ТАТАР

ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

# ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

БАШ МӨХӘРРИР М.Х.СӘЛАХОВ

6

Ш–Я

КАЗАН
ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ
2021

УДК 94(470.41):031
ББК 63.3(2Рос=Тат)2-64 я2
Т 23

ЖАВАПЛЫ МӨХӘРРИР
Г.С.САБИРҖАНОВ

Баш гыйльми мөхәрририят

М.Х.Сәлахов (рәис), И.А.Гыйләҗев (рәис урынбасары), Р.К.Абдуллин, А.Г.Әхмәдуллин, Н.М.Вәлиев, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, В.З.Гарифуллин, М.Г.Госманов, Р.Г.Госманов, М.З.Зәкиев, Г.Г.Җиһаншин, А.А.Җәләлов, Д.М.Исхаков, Е.П.Казаков, В.П.Кандилов, А.Н.Латышев, Х.Й.Миңнегулов, М.К.Михайлов, К.М.Салихов, М.М.Сәфәров, Н.А.Сәхибуллин, И.Р.Таһиров, Җ.И.Фәйзрахманов, Р.М.Харисов, Р.С.Хәкимов.

© ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2021.

РФнең «Авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турында» Законы нигезендә саклана.
Китап материалларын ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының язма рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

ISBN 978-5-902375-32-6

# Ш

**ШАБА́ЕВ** Марс Садри улы (14.7.1933, Минзәлә р-ны Югары Тәкермән а. – 22.2.2008, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1984). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1958). 1970 елга кадәр «Яшь ленинчы» г-тасында, «Азат хатын», «Чаян» ж-лларында, 1970–83 тә Татарстан китап нәшриятында, 1991 дән «Казан утлары» ж-лында эшли. «Шәймәт карт» (1956), «Яңа жыр» (1962), «Кына гөле» (1963), «Сине эзлим» (1966), «Әби-апа» (1967) һ.б. поэмаларда актив гражданлык позицияле хезмәтчәннәрнең якты образларын тудыра. Лирик һәм публицистик шигырьләрендә һәм балладаларында кешенең җәмгыятьтәге урыны, аның табигать б-н үзара бәйләнешләре турында фикер йөртә: «Җикән камыш» (1972), «Онытма...» (1973), «Җыр тәме» (1983). «Салда сәяхәт» повесте (1971) — туган җиргә мәдхия. Балалар өчен «Алып батыр кайчан чабатасын каккан?» (1987), «Чаба иде бер куян» (1990), «Гөрләвек» (2001) шигырьләр һәм әкиятләр җыентыклары авторы. У.Уитменның «Листья травы» («Үлән яфраклары», 1975) шигырьләр китабын, Е.Евтушенконың «Казанский университет», («Казан университеты», 1988) һәм «Мама и нейтронная бомба» («Әни һәм нейтрон бомба», 1988) поэмаларын, Р.Мир-Хәйдәровның «Ранняя печаль» («Иртәләгән сагыш», 2002) һәм «За всё — наличными» («Һәрнәрсәгә — акчалата», 2005) романнарын татар теленә тәрҗемә итә. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1976).

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1993; Сайланма әсәрләр. К., 2011.

*Әд.:* Ф ә й з у л л и н Р. Өлкәнебез // Казан утлары. 2003. № 7.

**ШАБА́ЕВ** Мирзаҗан Таһирҗан улы (9.6.1940, Оренбург өлкәсенең Абдулин р-ны Чаганлы а. — 8.6.1996, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1992), проф. (1991), ТАССРның атказ. икътисадчысы (1990). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук эшли, икътисад ф-ты деканы (1978–83), ректор (1985 елдан) һәм бер үк вакытта а.х.нда җитештерү б-н идарә итү каф. мөдире. 1990 нан ТР Югары уку йортлары ректорлары советы рәисе һәм РФнең ректорлар берлеге әгъзасы. Ш. институтның матди-техник базасы үсешенә, уку процессын камилләштерүгә, фән б-н җитештерүнең бәйләнешен ныгытуга зур игътибар бирә. Төп фәнни хезмәтләре агросәнәгать комплексында идарә итү, игенчелекнең интенсивлыгын, үсемлекчелек тармакларының, аерым алганда, бәрәңге үстерүнең нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләренә багышлана. ТАССР, КАМАЗ һәм АлАЗның шәһәр тирәсендәге а.х. зоналарында а.х. б-н идарә итү системасын эшләүдә катнаша.



М.С.Шабаев.



Б.С.Шабалин.

Х е з м.: Интенсификация земледелия в колхозах Татарии: уровень, эффективность, ускорение. К., 1986 (автордаш); Наш второй хлеб. К., 1989 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная сельскохозяйственная академия. 75 лет (Ист. очерк). К., 1997; Казанский государственный аграрный университет: История и современность. К., 2007.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ШАБА́ЕВ** Фаяз Баян улы (9.7.1966, Әгерҗе ш.), генерал-майор (2008). СССР Эчке эшләр министрлыгының Омск югары милиция мәктәбен тәмамлый (1987). 1987–90 елларда Казанның Киров р-ны эчке эшләр бүлегенең оперуполномоченные. 1990–93 тә Казан шәһәре Совет р-ны Эчке эшләр идарәсе башлыгы. 2003–2006 да Казан шәһәре Эчке эшләр идарәсе башлыгы. 2006–08 дә РФ Эчке эшләр министрлыгының Ерак Көнчыгыш федераль округы буенча Баш идарәсе башлыгы урынбасары. 2009–10 да РФ Наркотиклар әйләнешенә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Чуаш Респ-касы, 2010–16 да Татарстан Респ-касы буенча идарәсе башлыгы. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШАБА́Й** Мин Гариф улы (28.4.1913, хәзер БРның Кушнаренко р-ны Каратәкә а. — 5.9.1963, Казан), язучы. Сабый чагында ук ятим кала, бәхет эзләп ил гизәргә чыгып китә; 1931 елда караучысыз калган яшьүсмерләр колониясенә эләгә, шунда башлангыч белем ала, матур әдәбият б-н кызыксына башлый. 1934–38 дә Казан пед. ин-тында укый. Башкортстан вакытлы матбугатында эшли, әсәрләре Татарстан газеталарында һәм журналларында басыла. Лирик хикәяләр, очерклар, колхоз-совхоз театрлары өчен пьесалар яза. 1941 дә рев-циягә кадәрге авыл, татар һәм башкорт крәстияннәре тормышы турындагы «Уйналмаган скрипка» (1941) хикәяләр җыентыгын нәшер итә. 1942–49, 1950–55 тә репрессияләнә; аклана. 1955 тән Казанда. «Бездә ел буе яз» очерклар (1959), «Тормыш баскычлары» (1961), «Уяну» (1963; русчага тәрҗемәсе «Пробуждение», М., 1967), «Тормыш чакыра» (1964), «Якты өметләр» (1973) хикәя һәм повестьлар җыентыклары авторы.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1967.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**ШАБА́ЛИН** Борис Сергеевич (2.1.1916, Вятка губ. Алабуга ш. — 24.9.1962, Йошкар-Ола, Мари АССР), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), гв. капитаны. Чкалов танк уч-щесен тәмамлый (1942). 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1942 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 25 нче танк бригадасының танк ротасы командиры (5 нче гв. танк армиясенең 29 нчы танк корпусы). Дала, 2 нче Украина, 1 нче Балтыйк буе һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Корсунь-Шевченко, Умань-Ботошани (икесе дә 1944) һәм Көнчыгыш-Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 19 октябрендә Паланга шәһәре (Литва ССР) өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә: рота б-н алдынгы отрядта хәрәкәт итеп, дошман тылына үтә һәм беренче булып шәһәргә керә. Рота корпусның төп көчләренең Балтыйк диңгезе буена чыгуын тәэмин итә. 1946 дан запаста, Мари АССРда яши һәм эшли. Ленин ордены, ике Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ШАБА́НОВА** Людмила Борисовна (14.11.1950, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2007), проф. (2008). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), шунда ук эшли (1978–86). 1986 елдан читтән торып уку Совет сәүдәсе ин-тының Казан ф-лында укыта. 1998 дән Мәскәү коммерция ун-тының Казан коммерция ин-тында икътисад каф., 2000 нән хисап, финанс һәм банк эшләре каф. мөдире. Бер үк вакытта, 2003–10 да, Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында (Казан) факультет деканы. Төп хезмәтләре төрле өлкәдәге эшмәкәрлек, пр-тиеләрнең финанс хәленә анализ ясау һәм бәя бирү мәсьәләләренә багышлана.

Х е з м.: Маркетинговые исследования как разновидность прикладных НИР // Маркетинг. 2006. № 4; Потребительский рынок товаров и услуг и закономерности его развития // Социально-экономические явления и процессы. 2006. № 3/4; Прогнозирование жизненных циклов товаров // Практический маркетинг. 2006. № 7.

**ШАВЫ́РКИН** Алексей Иванович (21.1.1921, хәзер Чуаш Респ-касының Порецкий р-ны Тареевка а. — 12. 1.2000, Яшел Үзән ш.), суднолар төзүче, инженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979). Горький индустриаль ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), Яшел Үзән суднолар төзү з-дында эшли: цех технологы, бүлек башлыгы (1951), өлкән төзүче (1958 елдан), баш инженерның суднолар төзү буенча

урынбасары (1964 тән), директор урынбасары (1970 тән), заводның баш технологы (1978 дән), баш төзүче урынбасары (1982 дән), инженер (1990–96). Дәүләт бүләге төрле классны һәм төрле билгеләнештәге заманча хәрби корабльләр һәм гражданнар суднолары төзү технологияләрен үстерүгә һәм камилләштерүгә керткән өлеше өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШАГА́ЛОВ** Валерий Александрович (14.12.1955, Казан), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1979), шунда ук эшли. 1980 елдан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында. Хезмәтләре төш квадруполь резонансына, магнит-резонанслы томографиягә, физик экспериментны автоматлаштыруга багышлана. Дәүләт бүләге магнит-резонанслы «ТМР-0.06-КФТИ» томографын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

Х е з м.: Эхо в эффективном поле многоимпульсной ЯКР-последовательности // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1991. Т. 54, вып. 8 (автордаш).

**ШАД**, 1) Төрки каганлыкта яулап алынган терр-яләрдә каган наместнигы титулы; 2) Хәзәр каганлыгында — каганның идарәдәше титулы. Ш.ның вазифасы хәзәр атлы гаскәрен тотудан гыйбарәт була. Кайвакыт каганның улларын яисә ага-энеләрен Ш. дип атаганнар.

**ШАДИБӘ́К** (1380 тирәсе — 1412 тирәсе, Дәрбәнт ш.), Алтын Урда ханы (1399–1407). *Тимер Котлыгъ хан* үлгәннән соң, *Идегәй* әмир ярдәмендә хакимият башына килә. Ш. идарәчелеге номиналь булып, фактта Идегәй хакимиятне үз кулында тота. Бу дәвердә Урдада салым салу эше җайга салына, акча реформасы уздырыла; Алтын Урда гаскәре Мавәраэннәһерне (Амударья һәм Сырдәрья елгалары арасындагы төбәк) бөлдерә, Харәземне яулап ала (1405/06), Себердә *Туктамыш ханны* тар-мар итә (1406). Идегәйдән бәйсез булу максаты б-н Ш. аңа каршы фетнә куптарырга омтыла. Нияте барып чыкмагач, Дәрбәнттәге әмир Шәех Ибраһим янына барып сыена.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

*И.Л. Измайлов.*

**ШАДРА́ ҮЛӘ́Н** (Fritillaria), лаләчәләр семьялыгыннан суганчалы күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 180 гә якын төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Американың уртача поясында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Шахматсыман Ш.ү. (F. meleagroides) Идел алдында һәм Идел аръягында, рус Ш.ү.е (F. Ruthenica) Идел аръягында очрый. Дымлы болыннарда, даланган тау битләрендә, куаклар арасында үсә. 15–50 *см* биеклектәге үсемлек. Суганчасы ялпаграк. Сабагы нәзек, шома. Яфраклары чиратлашкан, кыяк, рус Ш.ү.ендә очы спиральсыман бөтерелеп тора. Шахматсыман Ш.ү.енең чәчәге берле, иенке, сабак очында урнашкан, чәчәк тирәлеге өлешләре кара-көрән-шәмәхә төстәге шахмат тәртибендәге тонык рәсемле яки тимгелле; рус Ш.ү.е чәчәге сабак очындагы сирәк чукта һәм өске яфраклар куентыгында, чәчәк тирәлеге кыңгыраусыман, кара кызыл. Җимеше — тартмачык. Апрель–майда чәчәк аталар. Җимешләре июньдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (яшь суганчалардан) үрчиләр. Декоратив үсемлекләр. Рус Ш.ү.е һәм шахматсыман Ш.ү.е ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ША́ДРИКОВ** Александр Валерьевич (1.1.1977, Чүпрәле р-ны Иске Чүпрәле а.), хакимият эшлеклесе. Казан пед. ин-тын (1998), Чуаш ун-тын (2006) тәмамлый. 1998–2001 елларда РФ Саклык банкының Чүпрәле бүлегендә эшли, 2001–02 дә ТР Икътисад һәм сәнәгать министрлыгы системасында — Чүпрәле р-ны буенча икътисад бүлеге башлыгы. 2002–05 тә ТР Төзелеш, архит-ра һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы техник инвентарьлаштыру бюросының Чүпрәлә участогы башлыгы. 2006–11 дә Чүпрәле муниципаль р-ны башлыгы урынбасары. 2011–13 тә Ульянов шәһәренең Зөя аръягы р-ны хакимияте башлыгы урынбасары, башлыгы. 2013 тә Чүпрәле муниципаль р-ны башкарма ком-ты җитәкчесе, 2013–18 дә башлыгы, район советы рәисе. 2018 дән ТР экология һәм табигать байлыклары министры.

Ш. Чүпрәле р-нында эшләгән чорда ТРның юл төзелеше, мәгариф һәм мәктәпкәчә балалар учреждениеләре биналарын, торакларны, социаль-мәдәни максатлардагы объектларны капиталь төзекләндерү һәм аларның яңаларын төзү өлкәсендәге Президент программасы уңышлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

**ША́ДРИН** Адихан Измаил улы (1.7.1929, Пенза өлкәсенең Инсар р-ны Яндовище а. – 15.1.2011, Әстерхан ш.), язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Рус телендә яза. Әстерхан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), Әстерхан өлкәсендәге авыл мәктәпләрендә укыта. 1956–73 елларда өлкә радиосында, «Комсомолец Каспия», «Волга» г-таларында, «Нижняя Волга» китап нәшриятының Әстерхан бүлекчәсендә эшли. 1973–97 дә Россия Язучылар берлегенең Әстерхан өлкә оешмасында җаваплы сәркәтип. «Сумала исе» («Запах смолы», Волгоград, 1968), «Турган кош» («Турган-птица», М., 1981), «Гаделсез мәхкәмә» («Суд неправедный», Әстерхан, 1995) романнары, «Лизавета» (Волгоград, 1976), «Иске юл» («Старая дорога», М., 1985), «Карьера» (Волгоград, 1989), «Кара аргамак» («Чёрный аргамак», Әстерхан, 2001) пьесалары, «Чуалыш» («Смута», М., 1989) дилогиясе, балалар өчен әсәрләр (әкиятләр, хикәяләр, повестьлар) авторы. Иҗатының төп темалары — кешенең җир-анага мөнәсәбәте, тормышта кешенең урыны, Идел һәм Каспийның экология мәсьәләләре, яхшылык б-н яманлык, табигать б-н цивилизация көрәше. Ш. әсәрләре автобиографик хасиятле, нечкә психологизм б-н аерылып торалар.

Ә с ә р.: Белуга: Избр. Астрахань, 2007.

*Әд.:* А н д р е е в Ю. Аспекты. Л., 1985; Т р а в у ш к и н Н. У Волги, у Каспия. М., 1985.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ША́ДРИН** Виктор Матвеевич (17.10.1930, Мөслим р-ны Яңа Усы а.), спортчы (байдаркада һәм каноэда ишү), СССРның спорт остасы (1957), психол. фән. канд. (1967). Казан ун-тын (1954), Казан пед.ин-тын (1962) тәмамлый. Спорт б-н 1951 елда «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятендә (Казан) шөгыльләнә башлый. РСФСР (1952), СССР (1953–55, 1957–60), Европа (1957, көмеш., К-1; бронза., К-4) чемпионатларында, РСФСР (1956), СССР (1959) халыклары спартакиадаларында 1000 һәм 10000 *м* лы дистанцияләрдә байдаркада ишү буенча җиңүче. 1954–2008 дә Казан ун-тында укыта, физик тәрбия каф. мөдире (1967–91). РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2000).

**ША́ДРИН РАЙОНЫ́**, *Курган өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 4,1 мең *км*². Үзәге — Шадринск шәһәре (Курганнан 146 *км* төньяк-көнбатыштарак; административ район составына керми). Ш.р.нда — 25691 кеше, район үзәгендә 75623 кеше яши (2017). 2002 елгы халык исәбе буенча, районда һәм Шадринскида 3082 татар исәпләнә. Алар, тупланып, Шадринскида (1683 кеше), Йолдыз (Әчкен) (659), Байрак (134), Сибирки (Яңавыл) (135) авылларында яшиләр. Йолдыз авылында ел саен *Сабан туе* уздырыла, мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. «Очкын кызлары» һәм «Миләш» (Йолдыз а.), «Дуслык» (Шадринск ш.) сәнгать коллективлары эшли. Йолдыз һәм Сибирки авылларында мәчетләр бар. Ш.р.нда Сов.Союзы Герое Х.Г.*Гыйззәтуллин* туган.

**ШАЙТА́Н** (борынгы семит телендә شايطان — дошман), исламда *Аллаһка*, кешеләргә дошман булган явыз рухларның (җеннәрнең) төп категориясе. Кыямәт көненнән соң ул рухлар *Иблис* б-н бергә тәмугта (*җәһәннәмдә*) җәфаларга дучар ителә. Уттан һәм төтеннән яратылганнар. «Ш.» төшенчәсе Коръәндә 87 тапкыр («Иблис» — 11 тапкыр) искә алына һәм Иблиснең ихтыярын үтәүче Ш.ның явыз гамәлләрен тасвирлауда файдаланыла. Коръәндәге Ш. образында гадәти булмаган затлар турында исламга кадәрге һәм соңгырак, яһүди-христиан Ш.-иблис образы б-н бәйле күзаллаулар да бергә тупланган. Ш. кешеләрнең җенси теләкләрен, ләззәткә омтылышларын файдалана, дингә ышанучыларга дога кылырга комачаулап, Аллаһны оныттырырга тырыша, тылсымга һәм сихергә өйрәтә, гөнаһлы эшләргә диндарлык төсмере бирә; кем аңлы рәвештә аның вәсвәсәсенә бирелә, ул тәмугка эләгә. Дингә ышанучылар махсус догалар б-н Ш.ны куарга мөмкин. Коръәндә схематик рәвештә күзалланган Ш. соңрак мөселман риваятьләрендә, әкиятләрендә тәфсиллерәк тасвирлана.

*Әд.:* Тимергалин А.К. Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек. К., 2007; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991; Н а л и ч Т.С. Ангелы и другие сверхъестественные существа в исламе. М., 2009; Сакр Ахмад Х. Джинны. М.-СПб., 2012.

**«ШАЙТА́Н КАЛАСЫ́»**, к. *Алабуга шәһәрлеге.*

**ШАЙТА́Н ТАЯГЫ́**, у б ы р у т ы. (Onopordum), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 2 төре билгеле, Евразиядә таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — чәнечкеле Ш.т. (O. acanthium), Кама алдында һәм Идел алдында очрый. Ташландык урыннарда, торақлар янында, юл буйларында үсә. 2 *м* га кадәр биеклектәге үсемлек. Тамыры орчыксыман, юан. Сабагы туры, өске өлешендә тармаклы. Яфраклары чиратлашкан, озынча, чәнечкеле, тешле, аскылары сапчыл, өскеләре утырма. Чәчәкләре алсу-кызыл, шарсыман кәрзин чәчәк төркемендә. Җимешләре — бүрекчәле күборлыкча. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Җир өсте өлешләрендә инулин, сапонин, алкалоидлар бар. Халык медицинасында үләне тонәтмәсе бронхиаль астма, бөер, бәвел куыгы авырулары вакытында файдаланыла. Баллы үсемлек.


Чәнечкеле шайтан таягы.

**ШАЙТА́НОВ** Олег Львович (31.1.1950, Кострома ш.), галим агроном, а.х. фән. канд. (1995), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), ТРның атказ. агрономы (1989). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), Орлов өлкәсенең Новосиль р-ны «Шенский» с-зында, Тәтеш совхоз-техникумы уку-укыту хуҗалыгында (1975 тән) баш агроном булып эшли. 1979 елдан Лаеш р-ны «Үзәк» («Центральное») тәҗрибә җитештерү хуҗалыгының баш агрономы, 1987 дән директоры, 1997 дән лаб. мөдире, 2002 дән Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының игенчелекнең адаптив-ландшафт системаларын модельләштерү үзәге җитәкчесе. Дәүләт бүләге ТРда терлек азыгы җитештерү системасын эшләүдә һәм аны гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

*Әд.:* Люцерна на семена в Татарстане. К., 2003 (автордаш); Козлятник восточный в Татарстане. К., 2004 (автордаш); Виды и сорта многолетних трав с повышенным средообразованием для зелёных и сырьевых конвейеров Республики Татарстан // Нива Татарстана. 2010. № 1/2.

**ШАКИ́Р** Самат Фәтхерахман улы (14.4.1924, Арча кантоны Күәм а. — 28.10.1998, Казан), язучы, журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1984). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1957), авыл мәктәбендә укыта, 1958–62 елларда — Татарстан китап нәшриятында. Бөек Ватан сугышында катнаша; сугыш иҗатының төп темасына әверелә. «Үлемнән көчлерәк» (1969), «Ташлардагы язулар» (1975), «Үлемне җиңгән батыр» (1978), «Исемнәре мәрмәрдә» (1982), «Мәңгелек исемлектә» (1985) һ.б. очерк җыентыклары сугыш батырларына; «Легенда егетләре» (1965; русчага тәрҗемәсе «Парни из легенды», 1978) документаль повесте Сталинград янында һәлак булган Сов. Союзы Геройлары Р.Ибаррури, В.Г.Каменщиков, Х.В.Фәттахетдинов батырлыкларына багышлана. «Минем шатлыгым» (1962), «Яраннар чәчәк аткан» (1984), «Төнбоеклы күл буенда» (2004) һ.б. лирик шигырь җыентыклары, балалар өчен «Бәхетле көнем» (1951), «Чәчәкләр сөйләшә» (1964), «Кыңгырау чәчәкләр» (1988) һ.б. шигырь җыентыклары авторы. М.Хәйретдингә багышланган «Сугыш язмалары» (1968); сугыш кырларында һәлак булган татар язучыларының әсәрләрен, аларның тормышы һәм иҗаты турында очеркларны үз эченә алган «Абдулла Алиш» (1970), «Алар сафта» (1985) җыентыкларының автор-төзүчесе.

*Әд.:* Х ә й б у л л и н И. Йөрәккә кучкән язулар // Казан утлары. 1977. № 7.

**«ШАКИ́Р СОЛДА́Т» ЙОРТЫ́**, Казандагы архит-ра истәлеге. Яшьлегендә хәрби хезмәттә булганы өчен «Шакир солдат» кушаматы алган мещан Ш.Шәмсетдинов акчасына 1895–98 елларда милли-романтизм юнәлешенең эклектика стилендә төзелә. Ул табыш йорты һәм ак таштан салынган хуҗалык каралтылары (ат сарайлары, каретник, мунча һ.б.) булган зур утарның бер өлешен тәшкил итә. Ике катлы кирпеч бина буе б-н Тукай (элеккеге Тихвин-Екатерина) урамының кызыл сызыгына урнашкан һәм төрле зурлыктагы 3 күләмне берләштергән асимметрияле композиция тәшкил итә. Үзәк бинага уң яктан таррак, биегрәк булып калкып торучы, ишегалдына алып керүче а́ркасы булган янкорма тоташа. Рустланган архиволтьлы а́ркалы биек тәрәзәләр, куышлыклар, дагасыман керү а́ркалары, баскыч рәвешендәге аттиклы парапет, «сталактик» кәрнизләр, яссы аркатура һ.б. элементлар йортның урам яктагы фасадына мөселман Көнчыгышының милли-романтик колоритын бирә. Ишегалды ягы фасадларында бизәкләр юк. Үзәк бинаның сул өлешендәге икенче катында урам ягындагы утарның кирпеч а́ркалы капкалары б-н тоташтырылган ябык терраса урнашкан. Терраса бөтен комплексның төп үзенчәлеге булган манаралы чатыр түбә б-н төгәлләнә. Совет чорында терраса ябык бүлмәгә әйләндерелә, а́ркалы капкалар сүтелә, йортның эчке планы үзгәртелә. Торак йортлар буларак файдаланыла.


Казанда «Шакир солдат» йорты. 1895–98. Хәзерге күренеше.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995. *Х.Г. Надыйрова.*

**ШАКИРҖА́НОВ** Әнвәр Хафиз улы (1.5.1959, Лаеш р-ны Кече Елга а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2005). Башкортстан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), Башкортстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында: селекция бүлеге мөдире (1997 елга кадәр), үсемлекчелек буенча селекция үзәге җитәкчесе (1999 дан). Хезмәтләре уҗым культуралары селекциясенә карый. Көзге арышның «Чулпан 7», «Кунакбаев истәлегенә», көзге бодайның «Люстесценс 9», «Башкирская 10», көзге тритикаленың «Башкирский короткостебельный», судан үләненең «Якташ» сортлары авторы.

Х е з м.: Гибридизация — основа рекомбинационной селекции растений. Уфа, 2001 (автордаш); Методы и результаты селекции озимых зерновых культур в Республике Башкортостан. Уфа, 2004.

**ШАКИРҖА́НОВ** Әсрар Шакирҗан улы (15.6.1924, Чепья р-ны Пархода а. — 17.1.2003, Казан), фотожурналист, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981,1986). 1951–58 елларда Фрунзе, Пермь, Казан, Малмыж шәһәрләре пр-тиеләрендә эшче. 1956–60 та К.Якуб исем. матбугат комб-тында (Казан) фотограф, 1961 дә Техниклар сарае фотокомб-ты (Әлмәт) мөдире. 1962 дән «Волжская новь» (Казан), «Ленин ялаве» (Казан), «Вперед» (Питрәч р-ны) г-таларының һ.б.ның фотохәбәрчесе. 1967–87 дә «Советская Татария» г-тасында фотохәбәрче, фоторәсемнәре күп кенә бөтенсоюз һәм респ-ка газета-журналларын-





Ә.Ш. Ш а к и р җ а н о в. 1.«Туган як басуы». 1970 еллар; 2.«Буровойда». 1972.



Ә.Ш. Шакирҗанов.



Р.Ә. Шакирҗанов.

да басыла. Татарстандагы зур рәсми чараларны, Татарстан җитәкчелеге эшчәнлеген яктырткан әйдәп барган фотожурналистлар исәбенә керә. Фоторепортажларында, фотоочеркларында чор рухын, билгеле бер шәхеснең кабатланмас чалымнарын, хезмәт кешесен зур планда күрсәтергә омтыла. Ш. иҗатында аерым урынны КамАЗ төзелеше, Татарстанның нефть сәнәгате үсеше («Татарстанның зур нефте» һ.б. цикллар) били. Татарстан турындагы күп кенә китаплар һәм фотоальбомнар әзерләүдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Мәскәү, Казан, Әлмәт, Лениногорск, Түбән Камада уза. «Правда», «Известия», «Советская Россия», «Азат хатын», «Советская Татария» һ.б. газета-журналлар тарафыннан оештырылган халыкара бөтенсоюз һәм респ-ка фотоконкурсларында җиңүче һәм призлар иясе. ТАССРның, СССРның Журналистлар берлеге бүләкләре лауреаты (1981,1981). Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Я к и м е н к о И. «История пишется объективом...» // Советская Татария. 1976. 1 июня.

**ШАКИРҖА́НОВ** Мәсгуть Мәҗит улы (3.5.1951, Мамадыш р-ны Тәкәнеш а. — 9.3.2013, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2009). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1993 елдан), магнитоакустика лаб-ясе мөдире (2003 тән). Хезмәтләре акустикада һәм оптикада магнит диэлектриклар һәм ярымүткәргечләрдәге яңа физик күренешләрне эксперименталь һәм теоретик яктан тикшерүгә карый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011).

Х е з м.: Акустооптическая дифракция в гематите, обусловленная магнитоупругой модуляцией поляризаций оптических мод // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 2008. Т. 88, вып. 1 (автордаш); Антиферромагнитная коническая рефракция упругих волн в гематите // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 2010. Т. 91, вып. 7 (автордаш).

**ШАКИРҖА́НОВ** Мидхәт Фәйзелхак улы (27.8.1928, Чаллы кантоны Югары Суыксу а. — 8.12.2013, Казан), фотожурналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). Алабуга пед. уч-щесендә укый. Киномеханиклар курсларын тәмамлый (1952). 1959 елдан Казан телевидение студиясендә киномеханик, 1963–64 тә Казандагы фото һәм кино түгәрәкләре б-н җитәкчелек итә, 1964 тә Идел-Кама фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык-технол. ин-ты фәнни хезмәткәре. 1967–94 тә, 1997–2005 тә — «Ватаным Татарстан» г-тасы, 1995–96 да — «Сувар» г-тасы, 1997 дә — «Мәдәни җомга» г-тасы фотохәбәрчесе. Фото эшләре бөтенсоюз («Правда», «Известия», «Сельская жизнь») һәм респ-ка матбугатында басыла, Казан телевидение студиясе тапшыруларында күрсәтелә. Ш. иҗатының төп темалары — иҗади эшчәнлектәге кеше, Татарстанның иҗтимагый-сәяси тормышының актуаль проблемалары, халыкара элемтәләре һәм мәдәнияте, татар авылы тормышы. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* С ә ф ә р о в М. Мидхәт абый бизмәне // Мәйдан. 2003. № 5.

**ШАКИРҖА́НОВ** Рәшид Габдулла улы (23.11.1950, Бөгелмә ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998), техник фән. канд. (1983). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Казанда эшли: «Союзхимпромпроект» проектлау ин-тында, 1976 дан Идел углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1989 елдан). Хезмәтләре җиңел углеводородларның киң фракциясен, бензин һәм дизель ягулык компонентларын, парафин эретүче матдә алу технологиясен эшләүгә карый. ТР Дәүләт бүләге углеводород чималын җитештерү һәм күкертле кушылмалардан чистарту технологиясен эшләгәне өчен бирелә. Фәнни эшчәнлек нәтиҗәләре «Татнефть»АҖдә, Россиянең нефть һәм газ эшкәртү пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә.

**ШАКИРҖА́НОВ** Рәшит Әгълә улы (7.6.1949, Биектау р-ны Ямаширмә а.), корылма механикасы, пед., филол. өлкәләре галиме, техник фән. канд. (1990), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), РФ нең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2009). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), Казан архит-ра-төзелеш ун-тында эшли: 1993 елдан корылма механикасы каф. доценты, 2008 дән каф. профессоры, 2002 дән студентларны татар телендә укыту буенча методик кабинет мөдире. Хезмәтләре корылмалар динамикасына, милли мәгариф системасын үстерүгә, татар телендә фәнни-техник терминология мәсьәләләренә карый. Ш. татар телендә югары белем бирүне оештыру концепциясен, корылма механикасын татар телендә укытуның методик курсын тәкъдим итә; төзелеш, нефть сәнәгате буенча русча-татарча сүзлекләр төзи, вузлар өчен корылма механикасы (2008), физика (2018) дәреслекләре, уку кулланмалары чыгара. ТР Дәүләт бүләге ТР белем бирү системасында татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кертүне фәнни, укыту-методик һәм мәгълүмати-программалаштыру буенча тәэмин иткәне өчен бирелә. «Фән һәм тел» гыйльми-мәгълүмати ж-лының баш мөхәррире (1997–2015). «Ямаширмә мәктәбе — мәгърифәт чишмәсе» (2005), «Мәшһүр татар галимнәре» (2011) монографияләре авторы. Татарстан Респ-касы Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исем. бүләге лауреаты (2014).

Х е з м.: Татар теленең танып белү алгоритмын фән һәм җәмгыятьне үстерү өчен куллану // Фән һәм тел. 2002, № 4; Корылма механикасы: югары уку йортлары өчен дәреслек. К.. 2008; Об одном алгоритме решения неполной собственной проблемы при расчёте на колебания сложных конструкций типа фюзеляж // Изв. вузов. Авиац. техника. 1982. № 4 (автордаш); Уточнение суперэлементного метода сил при расчёте свободных конструкций на собственные колебания // Прочность, устойчивость и колебания тонкостенных и монолитных авиайионных конструкций. К., 1983; Русско-татарский политехнический словарь. К., 2016 (автордаш).

*Әд.:* К а м а л о в А. Рәшит Шакирҗановка 60 яшь // Фән һәм тел. 2009. № 2; Татар педагогик фикере антологиясе. Т. 2. К., 2016.

**ШАКИРҖА́НОВА** Даимә Сөләйман кызы (14.12.1923, Бөгелмә кантоны Исергәп а. — 26.12.1990, Казан), хакимият эшлеклесе, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1972). ВЛКСМ ҮК каршындагы Үзәк комсомол мәктәбен тәмамлый (Мәскәү, 1946). 1941–43 елларда Ютазы р-нының Кәрәкәшле урта мәктәбендә укыта. 1943–44 тә ВЛКСМның Ютазы райкомы секретаре, 1944–45 тә 1 нче секретаре, 1945–52 дә Арча райкомының 1 нче секретаре. 1946–49 да ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире, 1952–53 тә ВЛКСМның Казан өлкә ком-ты секретаре, 1953–56 да ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. 1956–64 тә ТАССР МС рәисе урынбасары. 1964–83 тә ТАССР МС каршындагы Матбугатта дәүләт серләрен саклау идарәсе башлыгы. ТАССР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл байрагы ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ШАКИРҖА́НОВА** Лена Галимҗан кызы (псев. Лена Шагыйрьҗан) (4.6.1945, Актаныш р-ны Пучы а. — 16.1.2017, Казан; Әтнә р-ны Күлле Киме авылында җирләнә), шагыйрә, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2000). ТРның халык шагыйре (2016). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1967). 1968–73 елларда ТАССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле җырчысы, 1974–87 дә ТАССР Дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында тәрҗемәче булып эшли. 1982 дә туган якка, чордашларга, яшьлеккә һәм мәхәббәткә багышланган «Мөлдерәмә күңел» исемле беренче җыентыгын бастыра. «Ышанам йөрәгемә» (1986), «Иман әлифбасы» (1993), «Шигырьләр, поэма» (1996), «Бożра вә Хөҗрә» (2002), «Хуш исләре җиһан гөлләренең» (2011) шигырь һәм поэма җыентыклары авторы. Ш. поэзиясенә лирик-публицистик характер, ш. у. үзенчәлекле аһәң, милли төсмер хас. «Сагынмаклык» (2005) китабында татар халкының күренекле шәхесләре — С.Хәким, Р.Яхин, С.Садыйкова турында истәлекләр, замандашларына поэтик багышлаулар, әдәби-тәнкыйть мәкаләләре тупланган. «Дөнья базары, яхуд Яңа Америка фаҗигасе» (2001) поэмасында, «Галәм кисәтүе» (2006) фәлсәфи поэма-аллегориясендә актив гражданлык позициясе, публицистик пафос чагылыш таба. Балалар өчен язылган шигырьләре («Канатлы ат», 1999) үсеп килүче буында татар әдәбияты

һәм теленә мәхәббәт тәрбияли. А.Пушкин, А.Ахматова, М.Цветаева, Низами әсәрләрен, Й.Баласагунинең «Котадгу белег» («Игелекле белем», 1995) поэмасының аерым бүлеген һ.б.ны татар теленә тәрҗемә итә. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2011).


Лена Г. Шакирҗанова

*Әд.:* Вәлиев-Барҗылы М.Х. Безнең урамнарның бәйрәме // Казан утлары. 1995. № 3; Рахмани Р. Шагыйрәнең язмыш келәме // Казан утлары. 2003. № 4; Вәлиулла И. Һәр шагыйрь — бер дәрья. К., 2006.

*Ф.Ф.Хәсәнова.*

**ШАКИРҖА́НОВА** Луара Галимҗан кызы (сәхнәдә Зөһрә Шакирҗан) (9.6.1950, Әтнә р-ны Күлле Киме а.), драма актрисасы, нәфис сүз остасы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996), ТРның халык артисты (2010). Казан театр уч-щесен (1970) һәм Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тын (1973) тәмамлый. Сәхнә эшчәнлеген, театр уч-щесен тәмамлаганнан соң, сөйләү остасы һәм Татар филармониясендә концерт программалары алып баручы буларак башлап җибәрә. 1973–79 елларда Татар респ-ка күчмә театры (хәзер Татар драма һәм комедия театры) актрисасы, аның сәхнәсендә Ләйлә («Туйлар узгач», Р.Батулла), Тамара («Ситуация», В.С.Розов), Роза («Сандугачлар килгән безгә», И.Юзеев), Тәнзилә («Нәзер», Т.Миңнуллин) рольләрен башкара. 1979–84 тә ТАССР Мәдәният министрлыгының театрлар бүлеге өлкән инспекторы, 1984 тән Татар акад. театры музее җитәкчесе. Бер үк вакытта режиссёр, сценарийлар авторы, ТРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле концертларын, театр актёрлары, язучылар һәм шагыйрьләрнең иҗат кичәләрен, татар язучылары һәм актёрлары иҗатына багышланган телевидение һәм радио тапшыруларын алып баручы, татар шагыйрьләренең әсәрләрен башкаручы. Режиссёр буларак, Хельсинкида (Финляндия) яшәүче татарлардан оешкан һәвәскәрләр коллективы б-н — «Беренче театр» (Г.Камал, 1991), «Асылъяр», «Галиябану» (М.Фәйзи, 1992, 1993), «Туйлар узгач» (Р.Батулла, 1994) һәм Нью-Йорктагы (АКШ) үзешчән татар коллективы б-н «Туйлар узгач» (Р.Батулла, 1995) спектакльләрен куя. Нәфис сүз остасы буларак, Мәскәү, С.-Петербург, Истанбул, Бакуда татар шагыйрьләре иҗатына багышланган концерт программалары б-н чыгышлар ясый. Татар театры сәнгатен, туган телне пропагандалаучы.

Хезм.: Татарский государственный академический театр имени Галиасгара Камала. Сто лет. = Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Йөз ел: В 2 т. К., 2009 (автордаш).

**ШАКИ́РОВ** Альберт Наил улы (17.10.1955, Баулы штп), нефтьче, геол.-минерал. фән. д-ры (2003), ТРның атказ. геологы (2001). Казан ун-тын тәмамлый (1978). «Татнефть» АҖдә эшли (1978–82, 1990–97), 1982–90 елларда «Нижневартовскнефтегаз» ҖБдә (Көнбатыш Себер), Уфа бораулау эшләре идарәсендә, БашНИПИнефтьтә. 1997 дән «Геотехнефтегаз» фәнни-тикшеренү үзәгендә (Мәскәү), ген. директор (1999 дан), директорлар советы рәисе (2006 дан). Хезмәтләре геология, геофизика һәм нефть чыганакларын эшкәртүгә карый. Баулы чыганагында яңа нефть ятмаларын ачуда катнаша. Ш. Татарстан, Башкортстан, Көнбатыш Себер терр-яләрендәге нефть чыганакларының геол. төзелеше үзенчәлекләрен ачыклый. Катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыруның яңа технологияләрен эшли һәм гамәлгә кертә.

Хезм.: Геология турнейского яруса Татарстана. К., 1999.

**ШАКИ́РОВ** Әзһәр Шәфикъ улы (22.2.1940, Азнакай р-ны Буралы а.), драма актёры, РСФСРның һәм ТРның халык артисты (1988, 2000). Мәскәүдә М.С.Щепкин исем. Югары театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1961), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Ненилло («Синьор Купьелло йортында раштуа», Э. де Филиппо, 1966), Кәриб («Шамил Усманов», А.Гыйләҗев, А.Яхин, 1967), Анджело («Чамасына күрә чарасы», У.Шекспир, 1968), Айдын (шул исем. әсәр буенча, Җ.Җаббарлы, 1969) кебек тәүге зур рольләрендә үк актёрның образны төзү, һәр роль өчен аның асылын ачарга ярдәм итәрдәй төп күренешләр таба белү сәләте ачыла. Ш.ның бөкре Надир мәхдүм һәм сак, шиклерәк Тимон («Сүнгән йолдызлар», 1971; «Зәңгәр шәл», 1977, К.Тинчурин), үз-үзенә артык ышанган, соңыннан исә мескен хәлгә төшкән Большов («Агай-эне — ак мыек», А.Н.Островский, 1972), нык рухлы Богатырёв («Бер төн», Б.Л.Горбатов, 1974) кебек төрле пландагы рольләрендә үзе тудырган образга тиешле масштаб бирү, герой холкының аеруча мөһим сыйфатларын көчәйтеп яктырту, каршылыклы якларының төп сәбәпләрен билгеләү осталыгы күзәтелә. Ул тудырган Таланов («Ябырылу», Л.М.Леонов, 1980) образы актёрның әхлакый сайланыш алдында калган зыялы кеше психологиясенә тирәнтен үтеп керүе б-н аерылып тора, Паратов («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский, 1983) образында Ш. тамашачыга акчаның кешегә һәлакәтле йогынтысын сәнгатьле һәм истә калырлык үтемле итеп җиткерә. Ш. иҗатында Аксак («Бичура», М.Гыйләҗев пьесасы буенча, 1989) образы аерым урын алып тора. Бу образ аша актёр героеның халыкның әхлакый тамырлары б-н бәйләнешен югалтуына, рухи сукырлыгының көннән-көн көчәя баруына тирән борчылуын җиткерә. Аның башкаруында Нурхәмәт, Галимулла («Ильгизар+Вера», 1991; «Хушыгыз!», 1993, Т.Миңнуллин), Туктамыш хан («Идегәй», Ю.Сафиуллин, 1994), Әлмөхәммәт («Әни


Ә.Ш. Шакиров Рамай ролендә («Чаткылар», Т.Гыйззәт).


Луара Г.Шакирҗанова.


Ә.Ш. Шакиров.

килде», Ш.Хөсәенов, 1999), Зариф карт («Телсез Күке», З.Хәким, 2004), Сәлим бай («Курчак туе», М.Гыйләҗев, Р.Хәмид; Г.Исхакый әсәрләре буенча, 2009) образлары тамашачыны эмоциональ бөтенлеге, масштаблыгы, күпмәгънәлеге, рухи дөньяларының тирәнтен ачылуы, зирәклеге һәм кешелеклелеге б-н таң калдыралар. Актёр ш.у. Фуат Дамирович («Бабайлар чуагы», И.Зәйниев),


Ә.Ш. Шакиров Зариф карт ролендә («Телсез Күке», З.Хәким).

Доктор («Банкрот», Г.Камал), Тимер («Хан кызы Турандык», К.Гоцци), остаз Осман («Минем исемем Кызыл», О.Памук), 3 нче вәзир («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт) һ.б. рольләрне зур уңыш б-н башкара. Татар. акад. театрының әйдәп баручы актёрларыннан берсе; татар милли театр сәнгатенең бүгенге казанышларын аеруча тулы яктырта. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1998). «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Илялова И. Театр имени Камала. К., 1986; шул ук. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

*И.И.Илялова.*

**ШАКИ́РОВ** Габделхак Шакир улы (10.3.1921, Мамадыш кантоны Түбән Ушма а. — 28.8.2005, Түбән Кама), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1986). Минзәлә а.х. техникумын (1968), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1952) тәмамлый. Мамадыш МТСнда тракторчы булып эшли (1937 елдан), «Мамадыш» с-зында бүлек идарәчесе (1948 дән), «Агробаза» к-зында партком секретаре (1949 дан), Мамадыш район башкарма ком-ты рәисе урынбасары (1952 дән), КПССның Дөбъяз (1953 тән), Мамадыш



Гыйльми Ш.Шакиров.



Җ.Ә.Шакиров.

(1955 тән) район ком-тлары секретаре, Мамадыш район башкарма ком-ты рәисе (1956 дан), Түбән Кама р-нының «Прикамский» (1959 дан), «Ватан» (1968 дән), «Түбән Кама» (1970–91) с-злары директоры. Ш. җитәкчелегендә хуҗалык югары җитештерү күрсәткечләренә ирешә: «Прикамский» с-зы КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл Байрагы, «Ватан» с-зы 5 тапкыр СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл Байрагы, «Түбән Кама» с-зы 3 тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл Байрагы б-н бүләкләнә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. *И.Н.Афанасьев.*

**ШАКИ́РОВ** Гайнулла Шәриф улы (1.7.1925, Мамадыш кантоны Катмыш а. — 1.9.2012, Казан), генерал-майор (1978). К.Е.Ворошилов исем. Химик һөҗүмнән саклану хәрби академиясен тәмамлый (1957). 1943 елдан Кызыл Армиядә: Арзамас һәм Павловский Посад шәһәрләре уку полкларында фронт өчен хәрби резервлар әзерләүдә катнаша. 1945 тән дәүләт объектларын саклау гаскәрләрендә хезмәт итә. 1957 дән Идел буе хәрби округында полкның химик һөҗүмнән саклану хезмәте башлыгы (Казан). 1962–67 дә ТАССР Гражданнар оборонасы штабының химик һөҗүмнән саклану хезмәте башлыгы. 1967–90 да ДОСААФның Татарстан өлкә ком-ты рәисе. Ш. җитәкчелегендә оборона-массакүләм һәм яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләү эшләре үткәрелә. Ш. спортның хәрби-техник төрләрен үстерү б-н шөгыльләнә. 1990 нан — запаста, 1997 дән ТРның РОСТО (ДОСААФ) ветераннар (пенсионерлар һәм инвалидлар) оешмасы рәисе. ТР ның Журналистлар берлеге әгъзасы (1973 тән). Хезмәтләре гражданнар оборонасы, яшьләрне хәрби-патриотик рухта тәрбияләү мәсьәләләренә багышлана. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Воспитать себе смену. М., 1976; По зову совести — Намус кушканга. К., 2003; Оборонному обществу — 80: История и деятельность ОСОАВИАХИМА–ДОСААФ–РОСТО Татарстана. К., 2007; Батырлык адымнары. К., 1982.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ШАКИ́РОВ** Гыйльми Шакир улы (23.7.1929, Лаеш р-ны Татар Янтыгы а. — 14.4.1991, Казан), ит комб-ты эшчесе, Соц. Хезмәт Герое (1981). Хезмәт эшчәнлеген 1941 елда Лаеш р-нының «Кызыл Ялкын» к-зында башлый. 1953 елдан Казан җитен комб-тында эшли, 1955 тән — Казан киез-киез итек комб-тында, 1957–89 да — Казан ит комб-тында, ит әвәләүче. 10 нчы бишьеллык (1976–80) йөкләмәләрен вакытыннан алда (8 айга) үти, 1981 ел йөкләмәләрен 419 *т* ит эшкәртеп (планнан тыш 252 *т*), 6 ноябрьгә үти. Рационализатор, комб-тта һәм тармакның башка пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән күп әһәмиятле башлангычларның инициаторы (ит эшкәртү өстәлен, вентиляция системасын камилләштерә, бу сизелерлек икътисади нәтиҗә бирә). Герой исеме җитештерүдәге алдынгы уңышлары һәм фидакарь хезмәте өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШАКИ́РОВ** Җәвит Әхмәтгали улы (2.1.1962, БАССРның Чакмагыш р-ны Әхмәт а.), актёр (сөйләм жанры), БРның атказ. артисты (2012), ТРның халык артисты (2012). Эстәрлетамак мәдәни-агарту уч-щесен (1983), Казан театр уч-щесен (1990), Казан мәдәният ин-тын (1990) тәмамлый. 1983–86 елларда Чакмагыш р-нының Тайнаш авылы мәдәният йорты директоры, 1986–87 дә шул ук районның мәдәният бүлеге мөдире. 1987–90 да Татар акад. театрында, Газиз («Күк капусы ачылса», Х.Вахит), староста («Ат карагы», Т.Миңнуллин) һ.б. рольләр башкара. 1990 нан Татар филармониясендә сөйләм жанры артисты: «Гармун алыйк әле, дуслар» (1990), «Гел бергә гомергә» (1996) һ.б. концерт программаларында чыгыш ясый. 1995–2005 тә — «Салават», 2005 тән «Илһам» җыр театрларында. Ел саен шигырьләр, юмористик әсәрләр, җырлардан торган яңа концерт программасы әзерли: «Бер-беребезгә без кирәкбез әле» (2003), «Гомер синсез үтмәсен» (2007), «Язмыш безгә сөю бүләк иткән» (2013) программалары аеруча танылу ала. РФ терр-ясендә татарлар тупланып яшәгән төбәкләр буйлап гастроль турлары уздыра. Сатирик хикәяләр, поэмалар, шигырьләр, үз концертлары өчен җырлар яза. Шулай ук хатыны З.М.*Шакирова* б-н бергә дә җырлый.



И.Г.Ш а к и р о в җитәкчелегендәге «Идел» вокаль-инструменталь ансамбле.

**ШАКИ́РОВ** Закир Шакир улы (18.11.1881, Уфа губ., Уфа өязе Карачы-Елга а. — 7.2.1970, Уфа ш.), педагог, тел белгече. 1902 елда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый, шунда ук укыта, 1912–15 тә А.Л.Шанявский исем. Мәскәү халык ун-тында укый. 1916 дан Уфа уку йортларында укыта, 1920–68 дә Уфа халык мәгарифе ин-тында (1929 дан Башкорт пед.ин-ты, 1957 дән Башкорт ун-ты), 1931–58 дә башкорт теле һәм әдәбияты каф. мөдире. 1913–16 да яңа ысуллы татар мәктәпләре өчен Россия тарихы һәм географиясе буенча уку-укыту ярдәмлекләре төзи. Хезмәтләре башкорт тел белеме, башкорт телен укыту методикасы мәсьәләләренә карый. Башкорт теленең фәнни терминологиясен булдыруда, рус графикасы нигезендә башкорт алфавитын һәм орфографиясен эшләүдә катнаша.

*Әд.:* Якты язмыш: З.Ш.Шакиров: тормышы һәм фәнни-педагогик эшчәнлеге турында библиографик очерк. К., 1996; Е р г и н Ю.В. Закир Шакирович Шакиров (1881–1968). Уфа, 2007.

**ШАКИ́РОВ** Илдар Нуретдин улы (15.6.1946, Буа р-ны Кызыл Каен а. — 31.5.2008, Чабаксар ш.), химик-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984), техник фән. канд. (1992), Чуаш АССРның атказ. уйлап табучысы (1981). Казан химия-технол. ин-тын (1970), Бөтенроссия стандартлаштыру һәм сертификацияләү буенча кадрларны кабат әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү ин-тын (Мәскәү, 1993) тәмамлый. 1970–2008 дә В.И.Чапаев исем. Чабаксар җитештерү берләшмәсендә эшли: лаб., бүлек башлыгы, сынау-сертификация үзәге директоры урынбасары, директоры. Хезмәтләре махсус химия өлкәсенә карый. Ш. прогрессив технологияне, югары җитештерүчән җиһазларны, махсус кулланышлы эшләнмәләрнең яңа төрләрен эшләүгә һәм гамәлгә куюга мөһим өлеш кертә. Дәүләт бүләге пиротехника эшләнмәләрен җитештерүдә махсус технол. комплексны булдырганы өчен бирелә. Уйлап табуга 52 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХСының бронза медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009.

**ШАКИ́РОВ** Илһам Гыйльметдин улы (15.2.1935, Сарман р-ны Яңа Бүләк а. – 16.1.2019, Казан), җырчы (баритон), ТАССРның, Каракалпак АССРның һәм РСФСРның халык артисты (1969, 1981, 1983). 1960 елда Казан консерваториясен (педагоглары Е.Абросимова һәм З.Байрашева) тәмамлый. 1960–92 дә Татар филармониясенең әйдәп баручы солисты, 1992–2010 да — сәнгать җитәкчесе. Милли муз. культураның иң популяр татар җырчыларыннан берсе, татар халык көйләрен һәм Татарстан композиторларының камера-вокаль музыкасын кабатланмас башкару остасы. Аһәңле, йомшак тембрлы, киң диапазонлы аеруча матур тавышка ия. Ш. иҗаты милли көйнең эчтә-

легенә тирәнтен үтеп керү осталыгы б-н сыйфатлана. Җырчы «Кара урман», «Тәфтиләү», «Әллүки», «Гөлҗамал» кебек борынгы озын татар көйләрен башкара. Ш. репертуарын милли фольклорның ул яңарткан үрнәкләре тәшкил итә: «Син сазыңны уйнадың», «Бик еракта идек без», «Карьят батыр», «Кораб» һ.б. җырлар; М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи, А.Ключарёв, Н.Җиһанов, З.Хәбибуллин, С.Садыйкова, Р.Еникиев һ.б.ның вокаль әсәрләре (ш.и. махсус аның өчен язылганнары); заманча эстрада җырлары; төрле халыкларның җырлары (башк., казакъ, үзбәк, әзәрб. һ.б.); үзе иҗат иткән «Гөлмәрьям», «Идел каеннары», «Очрашу көе» һ.б. Аның башкаруында «Җилләр исә», «Сәфәр», «Сарман», «Рәйхан», «Герман көе» кебек татар халык җырлары; С.Сәйдәшевнең «Хуш, авылым»,



И.Г.Ш а к и р о в. Р.Яхинга багышлана. «Филармониада». 2011.

«Әдрән диңгез», Р.Яхинның «Китмә, сандугач» җырлары кабатланмас булып яңгырый. Россиядә, якын һәм ерак чит илләрдә (Төркия, Финляндия) концертлар бирә. Җәмәгать эшчәнлеге алып бара: вокал конкурсларында жюри әгъзасы, ш.и. Р.Ваһапов исем. 1 нче Халыкара татар җыры фестиваленең жюри рәисе (2004); матбугатта, радио һәм телевидениедә чыгышлар ясый; яшь талантларны үстерүгә булышлык итә. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1970), Бөтенроссия «Алтын Аполлон» («Золотой Аполлон», 2000) бүләге лауреаты. Халыклар дуслыгы, Почёт, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Сарман р-ны, Казан шәһәренең мактаулы гражданы (2006). «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгендә ачылган концертлар залына Ш. исеме бирелә (2019).

*Әд.:* Илһам: Татар халкының мәшһүр җырчысы Илһам Шакировка 60 яшь. К., 1995; Илһам Шакиров: Истәлекләр, мәкаләләр, шигырьләр. К., 2005; Илһам Шакиров: Истәлекләр, фотолар, мәкаләләр, шигырьләр. К., 2010.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ШАКИ́РОВ** Камил Фаяз улы (10.4. 1935, Кукмара р-ны Зур Сәрдек а. — 10.9. 1983, шунда ук), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Соц. Хезмәт Герое (1966). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1966). Хезмәт эшчәнлеген 1946 елда Кукмара р-нының Сталин исем. к-зында башлый. 1946–56 да Грозный шәһәрендә ташчы, Яшел Үзәндә 2 нче ФЗӨ мәктәбендә мастер, Кукмара р-нының Яңил авылында ташчы һәм районның төзелеш оешмасында ташчылар бригадиры булып эшли. 1959–83 тә Кукмара р-нының «Коммунизмга», «Заветы Ильича» к-зларында рәис. Ш. җитәкләгән елларда (1959–80) «Коммунизмга» к-зы респ-када иң зур бәрәңге үстерүче хуҗалыкка әверелә. Бәрәңге җитештерү 9 мең *т* га җитә, сату — 5 мең *т*, 1 *га* дан уңышы — 230 *ц* тәшкил итә. Бөртекләрнең уңышы 1 *га* дан 4,6 *ц* дан 23,6 *ц* га, еллык савым уртача һәр сыердан 1947 *кг* нан 2871 *кг* га кадәр арта. Герой исеме җитештерүне арттыруда, бөртекле һәм терлек азыгы культураларын әзерләүдә ирешелгән уңышлары һәм техникадан югары җитештерүчән файдаланганы өчен бирелә. 1966–71 дә СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын, ике көмеш медале б-н бүләкләнә. Зур Сәрдек урта мәктәбе терр-ясендә Ш.ка бюст куела (1990).

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978): Док. очерки. К., 1984; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

*И.Н.Афанасьев.*

**ШАКИ́РОВ** Мансур Әкмәл улы (3.2.1937, Ленинград), электр техникы, техник фән. д-ры (1980), проф. (1982). 1961 елда Ленинград политехника ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, электр техникасының теоретик нигезләре каф. профессоры (1982 дән). Хезмәтләре электр чылбырлары һәм электрон схемалар теориясенә; турбо һәм гидрогенераторларның электромагнит кырларын диакоптика алымнары б-н модельләштерүгә (тикшеренүләрнең нәтиҗәләре оборона сәнәгатендә кулланыла) карый. Ш. теоретик электр техникасында яңа фәнни юнәлеш — электромагнит кырларның һәм электр чылбырларының схема анализын һәм диакоптикасын эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Преобразования и диакоптика электрических цепей. Л., 1980; Декомпозиционные алгоритмы анализа электромагнитных полей. Л., 1992.

**ШАКИ́РОВ** Мөхәммәтҗан Шакир улы (7.5. 1928, Мамадыш кантоны, хәзер Мамадыш р-ны Түбән Ушма а., — 20.8. 2007, шунда ук), агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1984). ТАССР А.х. министрлыгының колхоз рәисләре әзерләү буенча Татарстан урта а.х. респ-ка мәктәбен тәмамлый (Казан, 1956). 1944–89 елларда Мамадыш р-нында: тракторчы, «Кызыл флаг» к-зында рәис урынбасары, агроном, рәис (1959 дан); 1957–59 да Түбән Ушма авыл советы рәисе. Ш. җитәкләгән елларда колхозда матди-техник база һәм социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла, юллар, күперләр төзелә, Түбән Ушма һәм Хафиз авылларына газ кертелә; бөртекле ашлык җитештерү — 2,2, бәрәңге — 2, сөт — 7, ит — 5,6 тапкыр, бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 6,1 *ц* дан 16,9 *ц* га, уртача еллык савым һәр сыердан 2140 *кг* нан 4045 *кг* га кадәр арта. Җитештерүнең табышлылык дәрәҗәсе 47,4% тәшкил итә (1989). Ленин ордены, дүрт Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*



И.Г.Шакиров.



К.Ф.Шакиров.

**ШАКИ́РОВ** Нур Хәмзә улы (21.7.1946, Арча р-ны Иске Кишет а.), инженер-механик, техник фән. канд. (1996), сәнәгый җитештерүне оештыручы. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1969). 1963–81 елларда Казан моторлар төзү ҖБ дә (бүленеп): токарь, мастер, цех, җитештерү-диспетчерлык бүлеге башлыгы, заводның җитештерү башлыгы урынбасары (1977 дән). 1981 дән «Мединструмент» ФҖБ ген. директоры, 1987 дән «Казан медицина инструментлары заводы» АҖ директоры, 1990 нан ген. директоры. Мед. сәнәгате үсешенә зур өлеш кертә. Ш. җитәкчелегендә пр-тиедә реконструкция уздырыла, яңа куәтләр сафка баса; мед. техникасының халыкара югарылыкка туры килгән яңа төрләрен җитештерү үзләштерелә. РФ, ТР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1999, 2017). Почёт ордены, медальләр, ТР Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ШАКИ́РОВ** Рафил Сабир улы (3.10.1941, Кукмара р-ны Сабанчы а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2001), проф. (2005), ТРның атказ. агрономы (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2006). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1965), Биектау р-нының «Таң» к-зында баш агроном булып эшли. 1966–68 елларда Ульянов а.х. тәҗрибә станциясендә. 1969 дан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында: лаб. мөдире (1979–88), агрохимия бүлеге мөдире (1988–2003 һәм 2007 дән), технол. үзәк җитәкчесе (2004–06). Хезмәтләре Урта Идел буенда, ш.и. ТРда биол. факторлар нигезендә игенчелекне интенсификацияләп, а.х. культураларын игү өчен ресурс саклау технологияләрен эшләү мәсьәләләренә карый (ТР Дәүләт бүләге, 2006).

Х е з м.: Земное плодородие. Уроки прошлого. Проблемы. Поиски. К., 1989; Возделывание озимой пшеницы. К., 2008; Возделывание озимой мягкой пшеницы в Республике Татарстан (рекомендации). К., 2009 (автордаш).

*Әд.:* Ведущие учёные // Нива Татарстана. 2006. № 5/6.

**ШАКИ́РОВ** Роберт Вафа улы (29.8.1938, Биектау р-ны Олы Битаман а.), педагог, халык мәгарифе эшлеклесе, тарих фән. д-ры (1981), пед. фән. д-ры (1997), проф.(1994), РФнең атказ. мәктәп укытучысы (1997). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1964), Биектау р-нының Рус Алаты авылы мәктәбендә укыта. 1965 елдан ВЛКСМның Биектау районкомтының 1 нче секретаре, 1968 дән Казан ун-тында. 1971 дән ТАССР мәгариф министры урынбасары, 1978 дән Әфганстан Демократик Респ-касы мәгариф министры ки-



В.М.Шакирова.



З.М.Шакирова.

ңәшчесе.1982 дән ПФАнең һөнәри техник пед. фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан), 1988–2006 да Казан кооператив ин-тында, 1991–2004 тә ректор. 2008 дән Социаль һәм гуманитар белемнәр ин-тының менеджмент каф. мөдире. Хезмәтләре пед. тарихы һәм пед. фикер мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Больше века на службе людям: Из истории потребительской кооперации Республики Татарстан. К., 1995 (автордаш); Школа и общество: Системно-концептуальный анализ реформ образования в России в XX веке. К., 1997; Казанская педагогическая школа во второй половине XX века. К., 1999; Управление проектами: Учеб. пособие. К., 2013; Учебно-методическое обеспечение образовательной дисциплины: Учеб. пособие. К., 2016.

**ШАКИ́РОВ** Рузалин Хәсән улы (20.9.1933, Буа р-ны Кайбыч а. — 14.10.1999, Казан), вет. анатомы, вет. фән. д-ры (1983), проф. (1984), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлый (1960), 1962 елдан шунда ук эшли, анатомия каф. мөдире (1983 тән), бер үк вакытта зооинженерлык ф-ты деканы. Хезмәтләре хайваннарның макро-микроморфологиясе закончалыкларын һәм, иннервацияләнүче әгъзаларның төзелешенә бәйле рәвештә, үңәч һәм ашказаны нерв аппаратының төр үзенчәлекләрен өйрәнүгә карый. Ш. беренче булып озын пилорик һәм күкрәкнең эчке нервлары морфологиясе формалашу чыганакларының үзенчәлекләрен ача. ТР Дәүләт бүләге бирелә (1999, үлгәннән соң). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Макро-микроморфология нервного аппарата печени крупного рогатого скота. К., 1988; Микроморфология позвоночного нерва крупного рогатого скота. К., 1992.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

**ШАКИ́РОВ** Фәрит Хафас улы (8.8.1931, Казан — 30.7. 2010, шунда ук), агроэколог, биол. фән. канд. (1961), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1954). СССР ФА Урман ин-тының эрозия бүлегендә эшли (1984 тән), СССР ФА Себер бүлегенең Хакас урман һәм үзагач эрозиягә каршы көрәш ин-ты башлыгы (1958 дән), Татарстан Респ-касы а.х. тәҗрибә станциясендә агрохимия һәм туфрак белеме бүлеге мөдире (1962 дән), мелиорация каф. мөдире, бер үк вакытта Казан а.х. ин-ты проректоры (1968 дән), эрозиягә каршы комплексларны проектлау секторы мөдире, бер үк вакытта СССР А.х. министрлыгы Дәүләт җир ресурслары фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан тәҗрибә пункты мөдире (1975 тән), Казан техник ун-ты каршындагы Диагностика һәм физик-химик процесслар б-н идарә итү фәнни-тикшеренү ин-тының агроэкология бүлеге мөдире (1993–2002). Дәүләт бүләге Биектау р-ны «Чулпан» һәм Арча р-ны «Игенче» күмәк пр-тиеләре мисалында игенчелектә агроландшафт системасының теоретик нигезләрен эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашуы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Противоэрозионное земледелие. К., 1979; Казанская агроэкологическая школа: История становления, эстафета идей, методик, технологий. К., 2003; Агроландшафтное земледелие. К., 2004 (автордаш); Адаптация агроэкосферы к условиям техногенеза. К., 2006 (автордаш).

**ШАКИ́РОВ** Фәрит Шәүкәт улы (19.6.1965, Удмурт АССРның Воткинск ш.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1989), ТатНИПИнефтьтә эшли. Хезмәтләре нефть чыгару тармагы җиһазларын реконструкцияләүгә, эшләтүгә һәм коррозиядән саклауга карый. Дәүләт бүләге нефтьүткәргечләрнең ышанычлылыгын арттыру буенча технол. чаралар комплексын өйрәнү һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар.

**ШАКИ́РОВ** Фоат Гафи улы (9.1.1942, Кукмара р-ны Арпаяз а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1987), РФнең мактаулы нефтехимигы (2001). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), Алтай химик технол. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, лаб. башлыгы (1989 дан), баш технолог (1991 дән). 1994–2005 тә Бөтенроссия углеводород чимал фәнни-тикшеренү ин-тының (Казан) әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре азот к-тасы чыгарылмалары химиясенә һәм технологиясенә, нефть эшкәртүгә багышлана. Ш. махсус продуктлар (илнең оборона пр-тиеләрендә) җитештерү, углеводород чимал җитештерү һәм күкертле кушылмалардан чистарту өчен (илнең оборона пр-тиеләрендә; ТР һәм РФнең газ һәм нефть эшкәртү пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә) югары җитештерүчән хәвефсез технологияләр һәм аппаратлар эшли. Эремәләрнең кислоталылыгын бәяләүнең ысулларын тәкъдим итә. Уйлап табуга 32 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР Дәүләт бүләге (1974), ТР Дәүләт бүләге (1998) лауреаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Функция кислотности и кинетика химических реакций в различных шкалах концентраций. К., 2000.

**ШАКИ́РОВ** Шамил Касыйм улы (3.7.1951, Әлки р-ны Чуаш Кичүе а.), галим зоотехник, а.х. фән. д-ры (1998), проф. (2006), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), Питрәч р-ны «Искра» к-зында баш зоотехник булып эшли. 1974 елдан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында: лаб. мөдире (1993 тән), директор урынбасары (1999 дан), терлекчелек фәнни-технол. үзәге җитәкчесе (2006 дан). Хезмәтләре а.х. терлекләренең тукланануы, витаминлы-минераллы премикслар җитештерү мәсьәләләренә карый. Рапс җитештерү, эшкәртү, файдалану һәм киң кулланылышка кертүнең икътисади нигезләрен һәм фәнни нигезләнгән технологияләрен эшләүдә катнашканы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1997). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Научные основы протеинового и аминокислотного питания свиней. К., 2006; Корма Республики Татарстан: состав, питательность и использование: Справ. К., 2010.

**ШАКИ́РОВА** Венера (Әфият) Мансур кызы (11.10.1960, Казан), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2015). Казан театр уч-щесен (1983), Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тын (2012) тәмамлый. 1983 елдан Татар акад. театрында эшли, бер үк вакытта Казан музыка уч-щесендә (2007–09), Казан театр уч-щесендә (2009–13), Казан ун-тында (2012–13) укыта. Театр сәхнәсендә актриса тормышчан, психол. тирәнлек б-н сугарылган Нәсимә («Миңлекамал», М.Әмир), Нина, Нәфисә («Әниләр һәм бәбиләр», «Без китәбез, сез каласыз», Т.Миңнуллин), Зөләйха («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Екатерина («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Мәрфуга («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Регина («Ак калфагым төшердем кулдан...», И.Юзеев), Акбүре («Ахырзаман», Ч.Айтматов), Синьора Капулетти («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир) һ.б. рольләрне зур уңыш



В.М.Ш а к и р о в а *Жизель ролендә («Бабайлар чуагы», И.Зәйниев; сулда — Хәлимә Әмировна ролендә Н.Гәрәева).*

б-н башкара. Эсмеральда («Зифа», Н.Исәнбәт), Камилә («Бәхетсез егет», Г.Камал), Нечкә маржа («Җан Баевич», Г.Исхакый), Галия, Саҗидә («Кишер басуы», «Килә ява, килә ява...», З.Хәким), Фәүзия («Казан егетләре», М.Гыйләҗев), Жизель («Бабайлар чуагы», И.Зәйниев) һ.б. рольләре Ш.ны комик характерлар тудыру остасы да буларак таныта.

**ШАКИ́РОВА** Гайшә Исмәгыйль кызы (27.7.1942, Чиләбе өлкәсенең Коншак р-ны Мөслим а.), биолог, биол.фән. канд. (1982), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1997), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1966). Ульянов өлкәсе а.х. тәҗрибә станциясендә үсемлекләрне саклау бүлеге мөдире, Казан фарм. уч-щесендә биол. укыта (1968 елдан), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында әйдәп баручы хезмәткәр (1971–2001). Дәүләт бүләге ТРда игенчелекнең биол. факторлары ниигезендә бөртекле ашлык җитештерүдә ресурс саклау технологияләре эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Повышение сохранности каротина в травяной муке // Тр. Татар. НИИ сел. хоз-ва. 1976. Вып. 7; Новый природный препарат «Татарстан» // Нива Татарстана. 1999. № 1; Пигменты растений и их роль в повышении урожайности и качества продукции кормовых и зерновых культур. К., 2003.

**ШАКИ́РОВА** Диләрә Мансур кызы (7.12.1948, Казан), педагог, химик, химия фән. канд (1979), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1999), РФнең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1971), 1973 елдан шунда ук нәорганик химия кафедрасында эшли. 1983 тән СССР ПФАнең һөнәри техник пед. фәнни-тикшеренү ин-тында; 1990 нан СССР ПФАнең пед. тарихы һәм теориясе ин-тында. 1992 дән Татар-Америка региональ ин-тында проректор, 1996 дан ректор. 2007 дән Казан «Ай-Тэк» бизнес мәктәбе директоры, бер үк вакытта, 2009 дан, ТР ФАнең Гамәли семиотика фәнни-тикшеренү ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре каты фазалы реакцияләр химиясе, химия укыту методикасы, чагыштырма пед., фикерләүне үстерү технологиясе мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Неорганическая химия: компьютерная поддержка курса химии: В 2 т. М., 1991–92 (автордаш); Теория и практика планирования карьеры в школе и вузе. К., 2003 (автордаш).

**ШАКИ́РОВА** Зөлфия Мәскүр кызы (27.5.1965, БАССРның Чакмагыш р-ны Югары Аташ а.), җырчы, БРның атказ. артисты (2012), ТРның халык артисты (2012). Уфа сәнгать уч-щесен (1986), Башкорт. пед. ун-тын (2005) тәмамлый. 1990–95 тә Татар. филармониясе солисты, 1995–2005 тә — «Салават», 2005 тән «Илһам» җыр театрларында. Солист буларак та, Җ.Ә.*Шакиров* б-н бергә дә чыгышлар ясый. Җырлар авторы һәм башкаручы. Ш. репертуарын хәзерге татар һәм башкорт композиторлары җырлары, халык җырлары (700 дән артык) тәшкил итә. 30 га якын концерт программасы әзерли. Г.Әлмөхәммәдов исем. (Башкортостан, 1979), «Татар җыры» (1993) конкурслары лауреаты.

Ә с ә р.: Син – яфрак, ә мин – чәчәк. К., 2015.

**ШАКИ́РОВА** Лилиана Рәфыйк кызы (12.9.1965, Балык Бистәсе р-ны Балык Бистәсе а.), педагог, пед. фән. д-ры (2005), проф. (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1987), комсомол эшендә. 1989–2011 елларда Татар гуманитар-пед. ун-тының матем. укыту кафедрасында, бер үк вакытта, 2007–2008 дә, фәнни тикшеренү идарәсе башлыгы; 2011 дән Казан ун-тында. Хезмәтләре Казан матем. мәктәбе тарихы һәм Казан ун-тында матем. укыту мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Н.И.Лобачевский и математическая школа Казанского университета. К., 2001; Казанская математическая школа, 1804–1954. К., 2002; Математическое образование в университетах России: XIX век. К., 2005.

**ШАКИ́РОВА** Лия Закир кызы (9.2.1921, Уфа ш. — 29.7.2015, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1974), проф. (1975), ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1968), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1976, 1981). Башкорт пед. ин-тын тәмамлый (1942). 1948 елдан Казан пед ин-тының рус теле кафедрасында (исеме берничә тапкыр үзгәртелә), 1965–90 да каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1963–60 та, ПФАнең Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан ф-лы мөдире.Татар мәктәпләрендә рус теле өйрәнүнең заманча методикасын эшли, 1960 ның 2 нче яртысы — 1970 тә Ш. җитәкчелегендә дәреслекләр, уку китаплары, 4–10 сыйныф укучылары өчен методик ярдәмлекләр әзерләнә. 1990 елларда В.Ф.Габделхакова б-н бергә татар мәктәпләренең өлкән сыйныфлары өчен яңа дәреслекләр яза. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Научные основы методики обучения категориям вида и времени русского глагола в тюркоязычной (татарской и башкирской) школе. К., 1974; Основы методики преподавания русского языка в татарской школе. К., 1990.

**ША́КШИНО** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 45 *км* көньяктарак, Уратма елгасы буенда. 2010 елда 13 кеше (руслар) яши. 1710 нан Каенлы Төбәк исеме б-н мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Вознесение чиркәве (1910–16; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе, 2 су тегермәне, ашлык саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1609,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1897 дә — 920, 1906 да — 996, 1920 дә — 1005, 1926 да — 719, 1949 да — 295, 1958 дә — 112, 1970 тә — 193, 1979 да — 101, 1989 да — 8, 2002 дә — 5 кеше.

**ШАЛАБА́НОВ** Александр Константинович (22.3.1944, ЧАССР, Чабаксар ш. — 31.12.2013, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1987), проф.(2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1967), шунда ук Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, сүрүләр механикасы лаб-ясе мөдире (1988 елдан). 1998 дән Татар бизнеска булышлык итү ин-тының матем. каф. мөдире, 2007 дән проф. Хезмәтләре юка диварлы корылмалардагы стационар һәм тиз үтүчән процессларга карый. Ш. оптик голографик интерферометрия алымнары ярдәмендә статик һәм динамик йөкләнеш астында булган пластиналар һәм сүрүләрне тикшерә; типлаштырылган мәсьәләләрне чишү өчен голографик интерферометриянең 3 экспозицияле алымын тәкъдим итә. «Эконометрика» (2008) уку ярдәмлеге авторларының берсе. СССРның баскетбол буенча спорт остасы (1968).

Х е з м.: Голографическая интерферометрия и фототехника. К., 1990 (автордаш); Метод определения деформаций в оболочках на основе СИ голографической интерферометрии // Изв. РАН. Механика твёрдого тела. 1999. № 3; Three-exposure Method of FL Hologram Interferometry in Mechanics of Thin-walled Spatial Structures // Proc. SPIE. 1995. V. 2545.

**ШАЛА́ГИН** Михаил Моисеевич (28.10.1903, Уфа губ., Благовещенский волосте Трошкино а. — 13.9.1961, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1951), проф. (1953). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1927), БАССРның Дүртөйле р-ны участок хастаханәсе мөдире булып эшли, 1929 елдан Аскын р-нының район хастаханәсе мөдире. 1932 дән Казан ГИДУВында: 1 нче хирургия клиникасында, 1945 тән онкология каф. доценты. 1952 дән Казан мед. ин-тының оператив хирургия һәм топографик анатомия каф. мөдире. Бөек Ватан сугышы елларында Казан эвакуация госпитальләре консультанты. Хезмәтләре яман шеш авыруларын дәвалауда күкрәк читлеге хирургиясе ысулларын эшләүгә карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. СССРның сәламәтлек саклау отличнигы (1950).

Х е з м.: Бронхиальные свищи и их лечение. К., 1951; Острые и хронические раневые эмпиемы и их лечение. К., 1953; Очерки по лёгочно-плевральным осложнениям при проникающих ранениях груди. К., 1958.

*Әд.:* К о з ы р е в а И.В., Х а р и т о н о в И.Ф. Профессор Михаил Моисеевич Шалагин: Некролог // Казн. мед. журн. 1961. № 5; Казанский государственный медицинский университет (1804 — 2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**ШАЛТЫ́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 40 *км* көньяктарак, Югары Кандыз елгасы буенда. 2010 елда 596 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1730 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Шалты исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 мәчет (шуларның берсе 19 йөз ахыры — 20 йөз башында төзелә; архит-ра истәлеге), 2 су тегермәне була; базар, 16–23 гыйнварда ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6439 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Салих волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1963 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 1512, 1889 да — 1811, 1897 дә — 2001, 1910 да — 2480, 1920 дә — 2534, 1926 да — 2077, 1938 дә — 1381, 1949 да — 1310, 1958 дә — 1163, 1970 тә — 1265, 1979 да — 1001, 1989 да — 721, 2002 дә — 604 кеше.



Шалты авылы мәчете.
19 йөз ахыры – 20 йөз башы.

**ШАЛФЕ́Й**, ч е б е н к у н м а с г ө л (Salvia), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел, ярымкуак һәм куакчыл үсемлекләр ыругы. 700 гә якын төре билгеле, бөтен Җир шарында, күбесенчә субтропик һәм тропикларда таралган. Татарстан терр-ясендә 6 төре бар. Чуклы Ш. (S. verticillata) бөтен җирдә ; ябышкак Ш. (S. glutinosa), иенке Ш. (S. nutans), болын Ш.е (кызыл Ш.) (S. pratensis), дала Ш.е (S. stepposa), коры дала Ш.е (S. tesquicola) Идел алдында һәм Кама аръягында очрый. Урман буйларында, даланган болыннарда үсәләр. 30–100 *см* биеклектәге үләнчел үсемлекләр. Яфраклары гади яки каурыйсыман. Чәчәкләре кызгылт-шәмәхә, зәңгәр, сары, сабак очындагы катлаулы чук яки себеркәч чәчәк төркеменә җыйналган; таҗының өске иренчәсе башлыксыман. Җимеше — күпчикләвекчек. Май–августта чәчәк аталар. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчиләр. Дала Ш.е, коры дала Ш.е, чуклы Ш.ның яфрак һәм яшь ботакларында флавоноид, аксым һәм дуплау матдәләре, эфир мае һәм минераль тозлар бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе гастрит, чәнчүләр, бөер һәм бавыр авырулары вакытында кулланыла. Яфраклары ашказаны һәм күкрәк йомшартучы җыелмалар составына керә. Барлык төрләре дә — декоратив үсемлекләр. Ябышкак Ш., иенке Ш. ТРның Кызыл китабына кертелгән.


Чуклы шалфей.

**ШАЛЯ́ПИН** Фёдор Иванович (13.2.1873, Казан — 12.4.1938, Париж; 1984 елда Мәскәүгә күчерелеп җирләнә), җырчы (бас), Респ-каның беренче халык артисты (1918). 1890 га кадәр Казанда яши: чиркәү хорларында җырлый, опера, драма һәм оперетта труппаларында статист һәм хор җырчысы була; П.Чайковскийның Казан музыка сөючеләр җәмгыяте куйган «Евгений Онегин» операсында Зарецкий партиясен (1890), С.М о н ю ш к о н ы ң «Галька» операсында беренче тапкыр Стольник партиясен (1890, Уфа ш.) башкара. 1894 тә «Аркадия» бакчасында опера спектакльләрендә катнаша (С.-Петербург). 1894–95 тә Панаев театрында чыгышлар ясый (Казан). 1895–1922 дә Мария (1918–21 дә сәнгать җитәкчесе) һәм Зур театрларда, Мәскәүдә С.Мамонтовның хосусый рус операсында, Тифлис операсында (шунда ук Д.Усатовтан җыр дәресләре ала) һ.б.да җырлый. 1897, 1899, 1909 елларда Казанда гастрольләрдә була. 1922 дән чит илдә яши. Дөньяның төп опера сәхнәләрендә һәм киң танылган концерт залларында чыгышлар ясый. Төп опера партияләре: Мефистофель (шул исем. әсәр буенча, А.Бойто), Фауст (шул исем. әсәр буенча, Ш.Гуно), Сусанин, Руслан («Патша өчен яшәү», «Руслан һәм Людмила», М.Глинка), Тегермәнче («Русалка», А.Даргомыжский), Кончак хан («Кенәз Игорь», А.Бородин), Борис Годунов, Досифей (шул исем. әсәр буенча, «Хованщина», М.Мусоргский), Иоанн Грозный, Варяг кунагы («Псковитянка», «Садко», Н.Римский-Корсаков) һ.б. Җырчының зур концерт репертуары төрле чорлар һәм стильләрнең вокаль әсәрләрен үз эченә ала. Рев-ция елларында демократик аудитория арасында Ш. башкарган «Эй, ухнем!», «Дубинушка» һ.б. рус халык җырлары киң таныла. Гаҗәеп тавышы, искиткеч вокаль һәм актёрлык осталыгы җырчыга дөньякүләм танылу китерә. Дөнья муз. мәдәниятенә Ш. бәяләп бетергесез зур өлеш кертә. 1982 дән Казанда ел саен *Шаляпин Ф.И. исемендәге опера фестивале* уздырыла, 1999 да Казанда Ш.га һәйкәл куела (к. *Шаляпин Ф.И. һәйкәле*), Казанның бер урамы аның исемен йөртә. 3 нче дәрәҗә Алтын йолдыз, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Страницы моей жизни. М., 1976; Маска и душа. М., 1989.

*Әд.:* Г о л ь ц м а н С.В. Ф.И.Шаляпин в Казани. К., 1986; Ф.И.Шаляпин: Летопись жизни и творчества: В 2 кн. Л., 1988–89.


Ф.И.Шаляпин.


Ф.И.Шаляпин портреты, Б.М.Кустодиев эше. 1920. А.М.Горький әдәби-мемориаль музее. Казан.


Ф.И. Ш а л я п и н Борис Годунов ролендә (шул исемдәге әсәр буенча, М.Мусоргский).

**ШАЛЯ́ПИН КА́МЕРА ЗАЛЫ́**, Казанда, «Казан» милли мәдәният үзәге ф-лы. 1999 елның 29 августында ачыла, «Казан» милли мәдәният үзәге структурасына керә. 1873 тә Ф.И.*Шаляпин* чукындырылган Богоявление чиркәве янындагы чаң манарасы бинасында (1897, арх. М.Д.Михайлов; псевдорус стилендәге архит-ра истәлеге) урнаша, мәйданы 67,5 $м^2$. Тупланманың нигезен (480 гә якын саклау берәмлеге) танылган Петербург коллекционеры Ю.Ф.Котляровтан сатып алынган экспонатлар тәшкил итә. Экспозиция залның периметры буенча җиһазландырылган; анда документлар, ш.и. Шаляпинның автографлары, фоторәсемнәр, сирәк очраучы пластинкалар, открыткалар, афишалар, 19–20 йөзләр чигендәге типологик әйберләр: рояль, шәмдәлләр, вазалар һ.б. урнаштырылган. Кыйммәтле экспонатлар арасында —


**Шаляпин камера залы.** 1. Интерьер; 2. Экспозиция фрагменты; 3. Ф.И.Шаляпин хатларының төп нөсхәләре куелган экспозиция фрагменты.

Шаляпинның әтисе фоторәсеме куелган алтын медальон, артистның Петербургтагы фатирыннан китерелгән икона. Ш.к.з. каршында әдәби-муз. клуб, «Мәдәният, музыка, театр һәм сынлы сәнгать дөньясына тәүге адымнар» балалар студиясе эшли. 2007 дә ябыла. Директоры — И.А.Эделева (1999–2007).

2016 елдан «А.М.Горький һәм Ф.И.Шаляпин музее»ның 2 нче катында И.Ф.Шаляпинның тормышына һәм иҗатына багышланган экспозиция эшли башлый. Коллекциядә Ф.И.Шаляпинның 87 берәмлек шәхси әйберләре, ул яшәгән чорга караган 4 меңнән артык тарихи ядкәрләр тупланган.

*Әд.:* Эделева И. Один из символов Казани // Казань. 2002. № 11/12; шул ук. Приметa духовной традиции и Камерный Шаляпинский зал // шунда ук. 58–61 б.

**ШАЛЯ́ПИН Ф.И. ИСЕМЕНДӘГЕ́ О́ПЕРА ФЕСТИВАЛЕ́**. 1982 елда Татар опера һәм балет театры тарафыннан оештырыла (оештыру эшен башлап җибәрүчеләр — ТАССР мәдәният министры урынбасары Р.М.Харисов, театр директоры Р.Мөхәммәтҗанов һәм баш дирижёр В.Куценко), 1985 тән — бөтенроссия, 1991 дән халыкара исемнәрен йөртә. Ел саен Казанда февраль аенда уздырыла. Фестиваль программалары, нигездә, Татар опера һәм балет театрында куелган премьера спектакльләреннән, ш.у. Ф.И.*Шаляпин* репертуарыннан алынган операларны да кертеп төзелә. Спектакльләрдәге төп партияләргә Россиянең әйдәп баручы башкаручылары, дөнья күләмендә танылган опера сәхнәсе йолдызлары, мәшһүр опера труппалары, иҗат коллективлары һәм соло концертлар куючы опера җырчылары чакырыла. Төрле елларда фестивальләрдә И.Архипова, Б.Минжилкиев, Д.Хворостовский, А.Ведерников, М.Биешу, И.Богачёва, Л.Казарновская, А.Кочерга, О.Бородина, С.Лейферкус, П.Бурчуладзе, О.Гурякова, Х.Герзмава, Н.Путилин, М.Казаков, В.Мороз, А.Агади, Р.Папе, А.Крутько, А.Шаһиморатова; дирижёрлар В.Гергиев, Р.Салаватов, М.Боэми, М.Крейчи, А.Москаленко; режиссёр-куючылар Г.Ковтун, М.Панджавидзе, А.Степанюк һ.б. катнаша. Фестивальдә катнашу өчен өметле яшь опера җырчылары да җәлеп ителә. Традиция буенча һәр фестиваль гала-концерт б-н тәмамлана. 2018 дә 36 нчы юбилей фестивале булып уза.



Шаляпин Ф.И. исемендәге опера фестивале. М.Мусоргскийның «Борис Годунов» операсыннан күренеш.





Шаляпин Ф.И. исемендәге опера фестивале. Опералардан күренешләр: 1. «Тылсымлы флейта», В.А.Моцарт; 2. «Мадам Баттерфляй», Дж.Пуччини.

**ШАЛЯ́ПИН Ф.И. ҺӘЙКӘЛЕ́**, Казанда. 1999 елда шәһәр үзәгендә Богоявление чиркәве янында ачыла. 1873 тә шул чиркәүдә Ф.Шаляпин чукындырыла, соңрак чиркәү хорында җырлый. Һәйкәлнең авторы — Мәскәү скульпторы А.В.Балашов. Бөек җырчы сыны концерт костюмында сурәтләнгән. Сул кулы йөрәгенә куелган, уң кулы салмак кына алга сузылган. Скульптор Шаляпинның йөз охшашлыгын, аның образының бөеклеген күрсәтеп бирүгә ирешкән. Һәйкәлнең гомуми биеклеге 5 *м* га якын, бронза фигураныкы — 4,1 *м*. Һәйкәл ачылышында Ф.Шаляпинның оныгы һәм оныкчыгы — Ирина Борисовна Шаляпина һәм Дася Шаляпина-Познер, ш.у. М.Шәймиев, Р.Миңнеханов, В.Матвиенко, К.Исхаков катнашалар. Ел саен 13 февральдә, Шаляпинның туган көнендә, һәйкәл янына аның талантын сөючеләр җыела.



Казанда Ф.И.Шаляпин һәйкәле. 1999. Скульпторы А.В.Балашов.

*А.В.Гарзавина.*

**ШАМА́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 60 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 434 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 45%, руслар — 40%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ит терлеге асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз уртасында отставкадагы солдатлар авылы буларак төзелә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Слобода Егорьевская исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элеккеге отставкадагы солдатлар) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Георгий чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), 2 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2471 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Биләр волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 668, 1897 дә — 1463, 1908 дә — 1632, 1920 дә — 1838, 1926 да — 1390, 1938 дә — 1179, 1949 — 835, 1958 дә — 710, 1970 тә — 669, 1979 да — 573, 1989 да — 476, 2002 дә — 468 кеше.

**ШАМА́НСКИЙ** Иосиф Львович (5.8.1926, Оренбург — 24.11.1995, Казан), геолог-икътисадчы, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995), геол.-минерал. фән. канд. (1962). Иркутск политехник ин-тын тәмамлый (1948). Көнбатыш Себер фәнни һәм житештерү оешмаларында эшли.1965 елдан ЦНИИгеолнерудта, икътисад һәм металл булмаган файдалы казылмаларны эзләү методикасы бүлеге мөдире (1966 дан). Хезмәтләре файдалы казылмалар геологиясенә һәм икътисадына карый. Ш. СССРның руда булмаган минераль чимал ресурсларын һәм респ-каның аерым икътисади районнарын геол.-икътисади яктан бәяләү картасын төзи. Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касында төзелеш материалларының минераль-житештерү комплексын үстерү проблемаларын геол.-икътисади яктан тикшерү һәм киләчәген дәлилләве өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШАМИ́Л ЙОРТЫ́**, Милли-романтик модерн стилендәге архит-ра истәлеге, Казанның Иске Татар бистәсендә урнашкан. Юнысовлар мәйданы ансамбленең мөһим өлешен тәшкил итә. 1903 елда архитекторлар Ф.Р.Амлонг һәм Г.Б.Руш проекты буенча И.И.Апаков йорты урынында (1863) аның кызы — генерал-майор М.Шамилнең (имам Шамилнең улы) хатыны Бибимәрьям заказы буенча төзетелә. Ике катлы кирпеч бина Екатерина урамында урнашкан (хәзер Тукай ур.), пыяла гөмбәз аша яктылык төшә торган үзәк



К.Ш. Шамил.



Ю. Шамил углы.

баскыч б-н бизәлгән. Урам ягы фасады үзәгендәге тирән куышлыкта төп керү юлы урнашкан, аның өстендә почмакларында уеплап эшләнгән кече манаралы турыпочмаклы эркер ясалган. Бинаны бизәүдә урта гасыр көнбатыш Европа архит-ра формалары (конус сыман түбәле эркерлар һәм баскычлы фронтоннар, тешле парапетлы манара, биек чатырлы кече манаралар б-н төгәлләнү) һәм модернга хас бизәлеш элементлары (тәрәзә йөзлекләре, колонналар һ.б.) файдаланылган. Әвәләп эшләнгән үсемлек һәм геом. бизәкләр бинага милли колорит бирә. Ш.й. 1980



Шамил йорты. Архитекторлары Ф.Р.Амлонг һәм Г.Б.Руш. Казан. 1903. Хәзерге күренеше.

еллар уртасында, 2006, 2011, 2017 дә төзекләндерелә. 1986 дан бинада Г.Тукайның әдәби музее урнаша.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995.

*Х.Г. Надыйрова.*

**ШАМИ́Л** Касыйм Шамил улы (30.8.1892, Казан губ., Чистай өязе Иске Әлмәт а. — 5.2.1981, Казан), драма актёры, режиссёр, педагог, ТАССРның халык артисты (1940). Татар проф. театрына нигез салучыларның берсе. Сәхнә эшчәнлеген 1909 елда «Сәйяр» труппасында башлап җибәрә, аннан соң «Нур» труппасында, Гражданнар сугышы елларында фронт театр бригадаларында, Казанда «Аң» труппасында эшли. 1920 нең язында Мамадышта «Сабанчы» театрын оештыра. Шул ук елның көзендә Ш. армия театр бригадасының җитәкчесе буларак хәрби частьларга хезмәт күрсәтү өчен Мәскәүгә җибәрелә. 1922 дә Казанда Беренче дәүләт татар драма театры труппасына керә. 1923–24 тә — Уфада татар театрында, 1924–28 дә Казанда Татар акад. театрында эшли. 1928–33 тә Әстерхан татар драма театры актёры һәм баш режиссёры, аның сәхнәсендә «Зәңгәр шәл», «Ил» (К.Тинчурин), «Наёмщик» (Т.Гыйззәт), «Хөсәен мирза» (Ф.Бурнаш), «Убылу» («Разлом», Б.А.Лавренёв) спектакльләрен куя. 1933 нең көзендә Казанга кайта, Үзәк пионерлар клубы каршындагы Казан яшь тамашачылар театры составында татар төркемен оештыра. 1934 тән Татар акад. театры актёры. Иҗатында тормыш хакыйкате б-н ачык театраль форма бергә үрелеп бара. Теге яки бу роль өстендә эшли башлаганда, актёр геройның үзенә генә хас үзенчәлекле тышкы билгеләрен табарга тырыша, эчке дөньясын яктырту өчен төгәл һәм таныш детальләрдән оста файдалана. Карап торышка көчсез һәм мәгънәсез күренгән Хәмзә («Беренче театр», Г.Камал), үзенә



К.Ш. Шамил Ортон ролендә («Тартюф», Ж.Б.Мольер).

буйсынучылар б-н үзен тәкәббер тотучы, ә җитәкчелеккә ялагайланучы Юсов («Төшемле урын», А.Н.Островский), Лука («Тормыш төбендә», М.Горький), хәйләкәр Полоний («Гамлет», У.Шекспир) образлары Ш. башкаруында тамашачыда тормышчан төгәл күзаллаулар тудыра. Ул иҗат иткән рольләр арасында Бәдри («Галиябану», М.Фәйзи), Суфый («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Әхтәри («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Шәйхулла («Тормыш җыры», М.Әмир), Баһави, Дәрвиш һәм Хуҗа Насретдин («Һиҗрәт», «Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Вәли («Аршин мал алан», У.Хаҗибәков), Кулигин («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский) һ.б. бар. Татар сәнгать техникумында (1934–39) һәм Татар театр уч-щесендә (1945–52) укыта, үзешчән сәнгать коллективлары б-н җитәкчелек итә. «Җәмилә», «Шомбай», «Аҗаган» (1956 да Татар акад. театрында сәхнәләштереләләр), «Тар тыкрыкта», «Сыйлаганда су эч» (1952 дә Татар респ-ка күчмә театрында сәхнәләштереләләр) пьесалары, татар театрлары актёрлары турында хатирәләр, биографик язмалар (кулъязмаларда) авторы.

*Әд.:* Шәрәфиев Ф. Касыйм Шамил. К., 1969; Иллялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; шул ук. Театр имени Камала. К., 1986.

*И.И.Илялова.*

**ШАМИ́Л УГЛЫ́** (Schamiloglu) Идел (3.5.1959, Нью-Йорк, АКШ), физик, физика-матем. фән. д-ры (1988), проф. (1988). Колумбия ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), Нью-Мексико штаты ун-тында эшли, импульслы энергия һәм плазма лаб-ясе җитәкчесе (1988 елдан), электр һәм компьютер машиналары төзү ф-ты пофессоры (2000 нән). Хезмәтләре корылмалы кисәкчәләр бәйләмен генерацияләү һәм тарату физикасына һәм технологиясенә, миллиметрлы тар һәм киң буйлы дулкыннар чыганакларына, плазма физикасына карый.

Хезм.: Rapid Start of Oscillation in a Magnetron with a Transparent Cathode // Phys. Rev. Lett. 2005. V. 95 (автордаш); Elemental Theory of a Relativistic Magnetron Operation: Anode Current // J. Directed Energy. 2010. V. 3 (автордаш).

**ШАМИ́Л УГЛЫ́** (Shamiloglu) Юлай (2.5.1958. Нью-Йорк ш., АКШ), тарихчы, тюрколог, философия д-ры (1986), ТР ФАнең чит ил әгъзасы (2008). Колумбия ун-тын тәмамлый (Нью-Йорк, 1979). 1983–89 елларда Индиана ун-тында (Блумингтон ш.) эшли. 1989 дан Висконсин ун-тында (Мэдисон ш.), проф. (2000). Үзәк Азия (2002 дән) һәм Якын Көнчыгыш (2006 дан) буенча тикшеренүләр программалары директоры. Америка төрки телләр укытучылары ассоциациясе президенты (2003 тән). Татар гуманитар-пед. ун-тының шәрәфле д-ры (2007). Хезмәтләре Алтын Урда, Россия мөселманнары тарихына карый.

Хезм.: The Golden Horde: economy, society and civilization in Western Eurasia, thirteenth-fourteenth centuries. Madison, 2006; Muslims in Russia, the growth and influence of islam in the nations of Asia and Central Asia. Phil., 2006.

**ШАМИ́ЛЬСКИЙ** (чын фамилиясе Вахитов) Шакир Габделгани улы (сент., 1892, Казан губ., Лаеш өязе Юеш Кәрнәле а. — 7.5.1945, Казан), драма актёры, режиссёр, ТАССРның атказ. артисты (1945). Беренче проф. татар актёрларыннан берсе, сәхнә эшчәнлеген 1912 елда «Нур» труппасында башлап җибәрә. Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышларында була, фронт театр төркемнәрендә катнаша. 1921 дә Казанда К.Тинчурин җитәкчелегендәге Беренче дәүләт татар театрына кабул ителә. Бер үк вакытта, 1922–40 та, Уфа, Әстерхан, Баку, Ташкент шәһәрләрендәге татар театрларында да актёр һәм спектакльләрне сәхнәгә куючы булып эшли. Образларның романтик күтәренкелеге һәм эмоциональ байлыгы, нечкә психологизм һәм тормышчан хаклык б-н сугарылган булуы аларга актёрның индивидуаль йөзен билгеләүче үзенчәлек һәм кабатлан-



Ш.Г. Шамильский Булат ролендә («Мәрьям», Н.Исәнбәт).

мас бөтенлек бирә. Ш. башкаруында тәкәббер Исмәгыйль («Галиябану», М.Фәйзи), буш, мәгънәсез һәм бернигә яраксыз Качкынский («Һиҗрәт», Н.Исәнбәт), һавалы демагог Батырхан, романтик ат карагы Миңлегали («Җилкәнсезләр», «Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), тормышта үз урынын таба алмаган Закир («Бәхетсез егет», Г.Камал), гыйсъянчы Васька Пепел («Тормыш төбендә», М.Горький), такылдык Кудряш («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), чын большевик Годун («Убылу» — «Разлом», Б.А.Лавренёв), гашыйк Фердинанд («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), ышанучан Отелло (шул исем. әсәр буенча, У.Шекспир) образлары тамашачыны иң элек хис-кичерешләр чынлыгы, гадәти булмаган пластик үзенчәлекләре б-н ышандыралар. Башка зур рольләре арасында Гайдай («Эскадра һәлакәте», А.Е.Корнейчук), Кузнецов («Габбас Галин», Ш.Камал), Булат («Мәрьям», Н.Исәнбәт), Мостафа («Ялкын», Т.Гыйззәт), Аркадий, Сафонов («Безнең шәһәр егете», «Рус кешеләре», К.М.Симонов), Кент («Король Лир», У.Шекспир) һ.б. бар. Режиссёрлык эшендә Ш. игътибарын пьесаның поэтик әчтәлегенә юнәлткән хәлдә тормыш хаклыгыннан да читкә тайпылмый, яшь шагыйрь һәм драматурглар иҗатына актив мөрәҗәгать итә. Татар. акад. театры сәхнәсендә М.Җәлил («Бибкәй кыз»), Һ.Такташ («Күмелгән кораллар»), Г.Кутуй («Тәхет йә мәхәббәт», «Нәнкә җан»), С.Баттал («Язулы яулык») пьесаларын, С.Җәләлнең «Дим буенда» повестен сәхнәләштерә. Ш. куйган аеруча зур спектакльләр — «Һиҗрәт» һәм «Мәрьям» (Н.Исәнбәт), «Рабиндар» (Х.Вафа), «Мәйсәрә хәйләләре» (Х.Хәмзә).



Ш.Г.Шамильский.

*Әд.:* Илялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; шул ук. Театр имени Камала. К., 1986; Арсланов Г.М. Татарское режиссёрское искусство. 1906–1941. К., 1992; шул ук. Татарское режиссёрское искусство. 1941–1956. К., 1996.

*И.И.Илялова.*

**ША́МИНА** Вера Борисовна (20.5.1950, Казан), әдәбият белгече, филол. фән. д-ры (2007). Горький пед. чит телләр ин-тын тәмамлый (1972). 1978 елдан Казан ун-тында. 19–20 йөзләр Америка драматургиясенә, Америка драмасының барлыкка килү, традицияләренең типологиясе мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр — «Америка драмасының ике гасыры» («Два столетия американской драмы», 2000); «Америка драмасының үсеш юллары: барлыкка килүе, типологиясе, традицияләре» («Пути развития американской драмы: истоки, типология, традиции», 2007) авторы.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2007): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ШАМИО́НОВ** Раил Мөнир улы (13.5.1969, Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Иске Кулаткы а.), психолог, психол. фән. д-ры (2002), проф. (2003). Ульянов пед. ин-тын «математика һәм физика» белгечлеге буенча (1991), Ленинград ун-тының психол. ф-тын (1992) тәмамлый. 1991 елдан Ульянов өлкәсе мәктәпләрендә укытучы, психолог. 1995 тән Иске Кулаткы р-нының Кирюшкино урта мәктәбе директоры. 1997 дән Саратов пед. ин-тының психол. кафедрасында (2004 тән Саратов ун-ты бүлекчәсе), 2004 тән белем бирү психологиясе кафедрасында, 2007 дән каф. мөдире. Хезмәтләре шәхеснең социальләшүе мәсьәләләренә карый.

*Хезм.:* Личность и её становление в процессе социализации. Саратов, 2000; Психология субъективного благополучия личности. Саратов, 2004; Социально-психологические аспекты становления и функционирования личности. Саратов, 2010 (автордаш).

**ШАМКА́ЕВ** Әкрәм Билал улы (22.10.1916, хәзер Оренбург өлкәсенең Матвеевка р-ны Иске Әшер а. — 12.8.1981, Шурчи ш., Үзбәкстан ССР), Сов. Союзы Герое (10.1.1944), старшина. МТСта тракторчы булып эшли. 1937–40 елларда һәм 1941 дән Кызыл Армиядә. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, моторлаштырылган понтон-күпер батальоны понтончысы (40 нчы армиянең 6 нчы понтон-күпер бригадасы). Брянск, Воронеж, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен сугышта Воронеж-Касторное, Белгород-Харьков һөҗүм операцияләрендә (барысы да — 1943), Яссы-Кишинёв (1944) һәм Братислава-Брно (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең октябрендә Днепр елгасын кичеп чыкканда батырлык күрсәтә: дошман уты астында сугыш техникасын паромда күчерүне тәэмин итә; 1943 нең 12 октябрендә Зарубинцы авылы янында (Черкассы өлкәсе Каневская р-ны) Днепр елгасы уртасында, снаряд ярчыклары эләгеп, катер сафтан чыга, Ш. кыска вакыт эчендә катерны төзекләндерә һәм уң ярга техниканы һәм кешеләрне күчерүне дәвам итә. Сугыштан соң демобилизацияләнә, колхозда, шуннан соң Шурчи шәһәрендә «Сельхозтехника» берләшмәсендә эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Шурчиның бер урамына Ш. исеме бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ШАМКА́ЕВ** Рәшит Мирза улы (Рәшит Шамкай) (26.5.1940, Куйбышев (хәзер Самара) өлкәсенең Камышлы р-ны Иске Ярмәк а.), драма актёры, ТАССРның халык артисты



Р.М.Шамкаев Хәсән ролендә («Ләйсән ире Хәсән», Ю.Сафиуллин).



Ә.Б.Шамкаев.



Р.М.Шамкаев.

(1987). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1966), Минзәлә татар драма театрында эшли. 1968–2001 елларда Татар акад. театрында. Истә калырлык комедия актёры буларак, Ш., авыл балагуры, тапкыр алдакчы рольләрен башкарып, иҗатында халыкчан фарс, балаган алымнарын оста файдалана.

Ш. тудырган истә калырлык сатирик Тишка («Агай-эне — ак мыек», А.Н.Островский), Пеләш («Әшнәләр», В.М.Шукшин хикәяләре буенча), Анчугин («Булмас димә, дөнья бу», А.В.Вампилов), Труффальдино («Болан Патша» К.Гоцци), Таһир («Әнә килә автомобиль», Ф.Яруллин), Ясәви («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Гыйльметдин («Ат карагы», Т.Миңнуллин), Дәрвиш («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Мөбарәк («Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре», М.Гыйләҗев), Нуретдин, 2 нче кунак («Су төбендә сөйгәнем», «Кишер басуы», З.Хәким) образлары бер үк вакытта тирән социаль мәгънәгә ия булулары б-н дә аерылып тора.

*Әд.:* Илялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

**ША́МОВ** Александр Георгиевич (29.9.1951, Төньяк Казакъстан өлкәсе Петропавловск ш.), химия физикасы белгече, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), Л.Я. Карпов исем. физика-химия фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү) эшли. 1975–93 елларда Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында, 1981 дән хисаплау техникасы бүлеге башлыгы. 1994 тән Казан технол. ун-тында: Мәгълүмат технологияләре үзәге директоры, Мәгълүматлаштыру бүлеге башлыгы (2004 тән). Хезмәтләре нитрокушылмаларның термик таркалышы параметрларын тикшерүгә карый. Дәүләт бүләге «Молекуляр структура, С- һәм О-нитрокушылмаларны барлыкка китерү һәм аларның мономолекуляр таркалышы» хезмәтендә катнашканы өчен бирелә.

**ША́МОВ** Афзал Шиһабетдин улы (4.3.1901, Казан губ., Зөя өязе Татар Танае а. — 19.1.1990, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе. Гражданнар, Бөек Ватан сугышларында катнаша. «Касыймия» мәдрәсәсендә, Казан ун-тының эшчеләр ф-тында (1922–25), 1 нче Мәскәү ун-тында (1926–31) укый. 1918 елдан авыл мәктәпләрендә укыта. 1931–43 тә Татарстан дәүләт нәшриятында мөхәррир, 1949–50 дә «Совет әдәбияты» ж-лы мөхәррире. 1958–61 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе. Язучының беренче хикәяләре



А.Ш. Шамов.



Я.Ф. Шамов.

1919 да нәшер ителә. Ш. иҗатының төп темасы — совет кешесенең рухи, гражданлык үсеше. Аның әсәрләрендә татар авылы тормышы, ике сугыш вакыйгалары, сугыштагы көрәштәшләре турында истәлекләр, соц. әхлак формалашу чагылыш таба. «Рәүфә» (М., 1928), «Бер мәхәббәт турында» (1935), «Хикәяләр» (1941) повесть һәм хикәя җыентыклары, «Көннәрдән бер көнне» (1959), «Яңгырлы кичтә» (1964), «Буранлы төндә» (1981) хикәя һәм очерк җыентыклары, «Чын хикәяләр» (1986), «Картлар» (1999) мемуарлар җыентыклары, публицистик язмалар авторы. Н.В.Гоголь, А.С.Пушкин, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, Ф.В.Гладков, В.Ф.Панова һ.б.ның әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Ф.Әмирхан (1957, 1 т.), Г.Ибраһимов (1975, 2, 3 т.; 1976, 4 т.) әсәрләре җыентыкларын басмага әзерли. Ш. әсәрләре рус, венгр, казакъ, чуаш, башкорт һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. 1959–63 тә ТАССР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1954.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**ША́МОВ** Булат Альфред улы (29.5.1962, Казан), педиатр, дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1985), Респ-ка балалар клиник хастаханәсендә эшли. 1986 елдан «Крутушка» санаториенда терапевт. 1992 дән Казан мед. ин-тының дерматовенерология кафедрасында. Хезмәтләре атопик дерматитны өйрәнүгә, аны дәвалауга (бигрәк тә мәктәп яшендәге балаларда), авыруны кисәтү ысулларын эшләүгә карый. 2002 дән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш дерматовенерологы. Уйлап табуга 2 патенты бар.

Х е з м.: Эндотоксин и состояние антиэндотоксиновой защиты у детей с атопическим дерматитом // Вестн. дерматологии и венерологии. 2002. № 1 (автордаш); Элидел — современная альтернатива наружным кортикостероидам в терапии атопического дерматита // Рус. мед. Журн. 2003. № 16; Основы дерматовенерологии: Социальная работа в дерматовенерологии. К., 2010 (автордаш).

**ША́МОВ** Георгий Фёдорович (15.4.1921, Амур өлкәсенең Зея ш. — 19.1.1990, Казан), тарихчы, тарих фән. канд. (1956). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1945), шунда укэшли, 1958–60 та тарих-филол. факультеты деканы, 1965–71 дә СССР тарихы каф. мөдире; 1960–65 тә ун-т проректоры. Бер үк вакытта, 1968 дән, КПССның Татарстан өлкә ком-ты Югары партия мәктәбе укытучысы. Хезмәтләре Россия тарихын өйрәнү методологиясенә һәм историографиясенә, Казанда шәркыять фәне, Россиядә 19 йөз ахыры — 20 йөз башы иҗтимагый-сәяси хәрәкәт тарихына карый.

Х е з м.: Восточный разряд Казанского университета // Очерки по истории русского востоковедения. М., 1956. Сб. 2 (автордаш); Изучение отечественной истории в Казанском университете // Общественно-политическое движение и классовая борьба на Средней Волге (конец XIX — начало XX вв.). К., 1972.

*Әд.:* Жить историей: 60 лет историческому факультету Казанского университета. К., 1999; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ША́МОВ** Яков Филиппович (1839, башка мәгълүматларга караганда, 1833 яисә 1838, Вятка губ. Орлов ш. — 30.11.1908, Казан), Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, иганәче, Казанның нәселдән килгән мактаулы гражданы. Орлов өяз училищесен тәмамлый. 1863 елдан Казанда, икмәк һәм тимер-томыр әйберләре б-н сату иткән эре сәүдәгәр Х.Ф.Фоминга хезмәткә керә; соңыннан аның кызына өйләнә, каенатасы үлгәннән соң, аның пр-тиеләрен мирас итеп алып кала. 20 йөз башында шәһәр тегермәнен арендага ала, үз флотилиясенә (100 мең сумлык пароход һәм 9 баржа) ия була. 1879 дан Казан шәһәр думасы гласные. 1883 тә император Александр III гә Таҗ кидерү комиссиясе әгъзасы. 1886 дан Казан *сәүдәгәрләр биржасы* старшинасы. *Сәүдәгәрләр банкы* идарәсе, Үзара кредитлау җәмгыяте рәисе. Казан шәһәре җәмәгать банкы (1879 дан), Дәүләт банкының Казан бүлеге (1888 дән) хисап ком-тлары әгъзасы. Казанда телсез-чукрак балаларны тәрбияләү һәм укыту җәмгыяте идарәсе рәисе һәм казначысы (1887 дән), Казан коммерция уч-щесенең попечительләр советы әгъзасы, 1887 дән Казан шәһәре Александр хастаханәсе попечителе (1898 дән попечительләр советы рәисе). 1907 дә Казан иске дин тарафдарлары җәмгыятен оештыручыларның берсе, аның советы рәисе. Шәһәр хастаханәсе (Шамов хастаханәсе) төзелеше һәм җиһазландырылуы өчен 500 мең сум чамасы, Казан коммерция уч-щесенең яңа бинасы өчен 25 мең сум, телсез-чукрак балалар уч-щесе бинасы өчен 5 мең сум акча тота. Орлов шәһәрендә аның акчасына суүткәргеч төзелә. Ш. шәһәр җәмәгать банкы барлыкка килүенә зур өлеш кертә. Васыяте буенча Ш.ның хатыны Ложкин гарипләр йортына 4 мең сум, Казан һөнәрчеләр җәмгыятенә 10 мең сум, Казанда балалар хастаханәсе төзелешенә 10 мең сум тапшыра. Иҗтимагый эшчәнлеге өчен Анна, Владимир һәм Станислав тасмалы өч алтын медаль, ике көмеш медаль, Кызыл Хач билгесе б-н бүләкләнә.

Чыг.: Яков Филиппович Шамов. Дар жителям Казани (к 100-летию Шамовской больницы): Сб. док. и материалов. К., 2008.

*Әд.:* Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана. К., 2001. Т. 2.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ША́МОВ ХАСТАХАНӘСЕ́**, к. *Казан шәһәре 1 нче клиник хастаханәсе* (2008 елда ябыла).

**ША́МОВА** Афина Гомәр кызы (22.9.1935, Казан), педиатр, мед. фән. д-ры (1987), проф. (1991), ТРның атказ. табибе (1997). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), Зеленодольск (Яшел Үзән) шәһәре балалар хастаханәсендә эшли. 1964–66 елларда Казан мед. ин-тының факультет терапиясе, 1972 дән госпиталь педиатриясе кафедраларында, 1990–2000 дә балалар авырулары каф. мөдире. 1966–72 дә Респ-ка клиник хастаханәсенең балалар авырулары бүлегендә. Хезмәтләре әйләнә-тирә мохитнең балаларда аллергия авырулары барлыкка килүгә йогынтысын, атопик дерматит очрагында иммун системасының яшькә бәйле үзенчәлекләрен өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 4 патенты бар. 1980–90 да ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш аллергологы. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эндотоксинемия и её роль в иммунных нарушениях при бронхиальной астме у детей // Казан. мед. журн. 2000. № 6 (автордаш); Роль грибковой сенсибилизации у детей с атопическим дерматитом // Казан. мед. журн. 2002. № 4 (автордаш); Атопический дерматит у детей. К., 2006 (автордаш); Аллергический ринит, бронхиальная астма и их сочетание у детей. К., 2007 (автордаш).

**ШАМО́ЗИТ** (Шамозон җирлеге атамасыннан, Швейцария), хлоридлар төркемендәге минерал. Балчыклы һәм оолитлы агрегатлар рәвешендә очрый. Соргылт-яшел, зәйтүнсыман-яшелдән кара төскә кадәр. Үтә күренмәле түгел. Уалучан. Катылыгы 2,5–3. Аккургаш рудаларының тимер һәм гидротермаль утырма чыганакларында барлыкка килә. Тимер рудасы сыйфатында файдаланыла. Татарстан терр-ясендә девон һәм яшьрәк катламнарда сидерит-Ш. һәм Ш.-гидрогётит-кальцитлы токымнар рәвешендә очрый.

**ШАМПИНЬОННА́Р** (Agaricus), агарикчалар семьялыгыннан эшләпәле гөмбәләр ыругы. 60 ка якын төре билгеле, бөтен Җир шарында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар — урман шампиньоны (A. silvaticus), кыр шампиньоны (A. arvensis), гади шампиньон (A. campester), һәркайда очрыйлар. Июньнән октябрьгә кадәр болын, кыр, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчаларында, терлек фермалары тирәсендә төркем булып үсәләр. Эшләпәсенең диаметры 3–25 *см*, көрән таңкәчекле ак-сыл-соры төстә. Пластинкалары аерым үсә, яшь гөмбәләрдә ак, картларында коңгырт-шәмәхә. Сабы төбенә таба юанаеп тора, гөмбә зурайгач ак элпәле боҗрасы юкка чыга. Йомшагы итчел, ак, сындырганда алсу яки кызгылт төскә керә, тәмле исле. Ш. культурада үстерелә. Яңа җыелган һәм консервланган килеш кулланыла.



Гади шампиньон.

**ШАМУ́КОВ** Габдулла Рухулла улы (11.12.1909, Сембер губ., Буа өязе Әсән а. — 21.12.1981, Казан), драма актёры, педагог, язучы, БАССРның атказ. артисты (1943), ТАССРның, РСФСРның һәм СССРның ха-

лык артисты (1950, 1957, 1980). 1930 елда Уфа сәнгать техникумының театр бүлеген, 1952 дә Казан пед. ин-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый, 1930–46 да Башкорт акад. драма театры актёры; Шаһгали («Зимагурлар», С.Мифтахов), Тукай (шул исем. әсәр буенча, Ә.Фәйзи), Подколесин («Өйләнү», Н.В.Гоголь), Ленин («Мылтыклы кеше», Н.Ф.Погодин) кебек шактый гына зур образлар иҗат итә. 1946 да Татар акад. театрына чакырыла (Казан). Ш. — күппланлы актёр, драматургиянең төрле



Г.Р. Шамуков.



Г.Р. Ш а м у к о в Ленин ролендә («Мылтыклы кеше», Н.Ф.Погодин).

жанрларында эшли, образга керү остасы, актёрларга хас сәнгатьчә чаралардан оста файдалана һәм һәр роленең төгәл пластик сурәтен гәүдәләндерү сәләтенә ия. Татар акад. театры сәхнәсендә милли, рус һәм дөнья драматургиясе әсәрләре буенча үзенчәлекле образлар галереясын тудыра: Клобуков («Диңгездәгеләр өчен», Б.А.Лавренёв, 1946), Ленин («Мылтыклы кеше», Н.Ф.Погодин, 1947) һ.б. рольләрне тормышчан һәм ышандырырлык итеп башкара. Зирәк һәм шук Труффальдино («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони, 1948), авантюрист һәм бушкуык Хлестаков («Ревизор», Н.В.Гоголь, 1949), гади һәм эчкерсез Дормедонт («Кичеккән мәхәббәт», А.Н.Островский, 1950), хәйләкәр һәм зирәк Насретдин («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт, 1952, 1957), куркак һәм аумакай Балтаев («Зифа», Н.Исәнбәт, 1954), һавалы, шау-шулы һәм түбән җанлы Нуретдин («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин, 1958) образларын иҗат итеп, актёр сәнгатьчә чаралар палитрасын гәүдәләндерә. Милләтче Мусаның әхлакый ярлылыгын («Американ», К.Тинчурин, 1969) һәм сөйкемле Телятевның рәхимсез ялганын («Котырган акчалар», А.Н.Островский, 1962) оста ача. Ә.Фәйзинең «Тукай» әсәре буенча куелган спектакльдә Ш. иҗат иткән халык шагыйре образы аның иҗатын яңа баскычка күтәрә (1961). Актёр Тукайның бай рухи дөньясын тулы итеп ачуга, әдипнең дөреслек өчен карагруһчылыкка һәм наданлыкка каршы көрәштә тәвәккәллеген оста яктыртуга ирешә. Аеруча зур рольләре — тынгысыз Купьелло («Бәйрәм кичендә», Э. де Филиппо, 1966), тәкәббер Ксанф («Кол», Г.Фигейредо, 1967), астыртын Актай («Кол Гали», Н.Фәттах, 1974), котылгысыз ялгызлык кичерүче клоун Блом («Канлы күләгәләр», Г.А.Боровик, 1975) һ.б. Ш. иҗат иткән характерлар барысы да мөлаемлылык, романтик күтәренкелек кебек сыйфатлар б-н аерылып тора.



Г.Р. Ш а м у к о в Тукай ролендә (шул исем. әсәр буенча, Ә.Фәйзи).



Г.Р. Ш а м у к о в Хуҗа Насретдин ролендә (шул исем. әсәр буенча, Н.Исәнбәт).

Театрда эшләү дәверендә Ш. бер үк вакытта Казан театр уч-щесендә укыта (1946–69), тәрҗемә б-н шөгыльләнә, шигырьләр, мәсәлләр, актёрларга багышланган биографик очерклар, теоретик характердагы мәкаләләр яза. А.С.Грибоедовның «Горе от ума» пьесасын, Эсхилның «Прикованный Прометей» драмасын, У.Шекспир, Ж.Б.Мольер, А.С.Пушкин, Н.В.Гоголь, А.Н.Островский пьесаларын татар теленә тәрҗемә итә. Нәфис сүз остасы буларак концертларда катнаша, радио һәм телевидениедә чыгышлар ясый. Ленин ордены б-н бүләкләнә. Казанда Ш. яшәгән йортка (1963 тән) мемориаль такта урнаштырылган.

Ә с ә р.: Уңган кыз. К., 1954; Нәкый Исәнбәт. К., 1959; Мәсәлләр. К., 1964.

*Әд.:* Г ы й м р а н о в а Д. Габдулла Шамуков. К., 1985; И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; ш у л у к. Театр имени Камала. К., 1986; Народные артисты. К., 1980; А р с л а н о в М.Г. Татарское режиссёрское искусство. 1957–1990. К., 2002.

*И.И.Илялова.*

**ШАМУ́Н** Фидаи (тәхәллүсе, чын исеме һәм фамилиясе Шакирҗанов Касыйм Хәсән улы) (15.6.1902, Оренбург ш. — июнь 1920), шагыйрь. 1916–17 елларда Оренбург татар-рус земство мәктәбендә, 1917–18 дә — «Галия» мәдрәсәсендә (Уфа) укый. 1917 елгы рев-ция һәм Гражданнар сугышы вакыйгаларында, Оренбургта комсомол оешмасын булдыруда катнаша. 1916 дан Уфада яши: губерна ком-ты әгъзасы, татар-башкорт коллегиясенең матбугат бүлеге мөдире, «Алга», «Кызыл Яу», «Яшь коммунист», «Яшь көч» г-таларында революцион рухтагы шигырьләрен бастыра. РКСМның 3 нче губерна съездында комсомолның Уфа губерна ком-ты әгъзасы, комсомолның 3 нче Бөтенроссия съезды делегаты итеп сайлана. Мәмәк авылы янында Совет хакимияте дошманнары кулыннан һәлак була. Шигырьләре «Октябрь җиле» (1960), «Йөрәк ялкыны» (1971) җыентыкларына кертелә. В.Маяковский, Э.Багрицкий шигырьләрен, М.Горький хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**ШАМУ́РИН** Евгений Иванович (16.10.1889, Ереван — 1.12.1962, Мәскәү), библиограф, пед. фән. д-ры, проф. (1944). Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1912). «Волжско-Камская речь» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә (әдәбият һәм сәнгать буенча мәкаләләр, театрлар эшчәнлегенә рецензияләр, муз. тәнкыйть). 1913 елда Мәскәүдә Ш. «Евгений Белов» псевд. б-н «Казан. Түбән Новгород. Кострома» («Казань, Нижний Новгород, Кострома» — «Культурные сокровища России» ж-лында, 4 чыг.) хезмәтен бастыра. 1914–1918 дә Казан хәрби округында хезмәт итә. 1919 дан Томск Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының юстиция бүлегендә хокук белгече. 1920 дән ТАССР Хезмәт халык комис-тының хезмәтне саклау бүлегендә лектор һәм консультант, бер үк вакытта Эшче-крәстиян Кызыл Армиясенең командирлар составы белемен күтәрү курсларында рус әдәбиятын укыта, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре буенча халык алдында лекцияләр б-н чыгышлар ясый. 1921 дә Татгосиздатта, библиография бүлеге мөдире, бер үк вакытта ТАССР Китап палатасы директоры. 1921 нең сентябреннән Мәскәүдә Россия (1936 дан — Бөтенсоюз) үзәк китап палатасында: «Китап елъязмасы» мөхәррире урынбасары, мөхәррир (1923), Китап палатасы директоры урынбасары (1932–1937 һәм 1945–49), Китап палатасының хакыйкый әгъзасы (1930 елларда Югары аттестация комиссиясе тарафыннан бирелгән гыйльми дәрәҗә) була. 1939 дан РСФСР Мәгариф халык комис-тының фәнни һәм массачыл китапханәләрне каталоглаштыру буенча бердәм инструкция эшләү өчен махсус комиссиясе рәисе. 1940–50 дә Мәскәү китапханә ин-тының фондлар һәм каталоглар каф. мөдире. Китапханәләр һәм библиография эшчәнлегенең матбугат ста-



А.Т.Шаповалов.

тистикасының оештыру, методология һәм фәнни-методик проблемалары өстендә эшли.

Х е з м.: Руководство по составлению алфавитного каталога. М., 1927; Методика библиографической работы. М., 1933; Алфавитный каталог и его организация. М., 1936; Систематический каталог и его организация. М., 1936; Очерки по истории библиотечно-библиографической классификации: В 2 т. М., 1955–59; Методика составления аннотаций. М., 1959.

*Әд.:* М а с а н о в Ю.И., Г р а ч ё в а И.Б. Е.И.Шамурин (1889–1962). М.,1970.

**ША́ПНИК** Михаил Самойлович (28.2.1932, Украина ССР, Винница өлкәсе Могилёв-Подольский ш. — 20.11.2009, Казан), электр химигы, химия фән. д-ры (1986), проф. (1988), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), Казанда С.М. Киров исем. ясалма каучук з-дында эшли, 1959–2009 елларда Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре нәорганик химиягә, теоретик электр химиясенә карый. Ш. кислород эчтәлекле лигандалы бакыр, көмеш, тутыя, кадмий, индий комплексларының катод һәм анод процессларын тикшерә, бу металларны төпкә утыртуның яңа технол. процессларын эшли (аларның кайберләре сәнәгатькә кертелә). Электрод процессларын турыдан-туры электрохимик күзәнәктә өйрәнү өчен ЭПР алымын куллану мөмкинлеген күрсәтә. Электрод өслекнең кластер моделе кысасында электролитларның кайбер молекуляр һәм ион тәшкилләгечләрен адсорбцияләү нәтиҗәләре буенча беренче булып мәгълүмат ала; комплекслы ионнар катнашында электрохимик реакцияләр механизмын билгели. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Квантово-химический подход к исследованию электродных процессов осаждения и анодного растворения металлов // Электрохимия. 1994. Т. 30, № 2; Новые аспекты микроскопического описания адсорбции цианид-ионов на серебре из водных растворов // Электрохимия. 1996. Т. 32, № 9 (автордаш); Структура комплексов меди (II) с разнородными лигандами по данным ЭПР // Журн. неорган. химии. 1998. Т. 43, № 5 (автордаш).

**ШАПОВА́ЛОВ** Александр Тимофеевич (9.11.1916, Успенка а., хәзер Ворошиловград өлкәсенең Лутугино р-ны Успенка штп — 29.7.1976, Казан), Сов. Союзы Герое (1.7.1944), гв. майоры. Кече авиация белгечләре мәктәбен (1941), Энгельс очучылар хәрби авиация уч-щесен (1947), Офицерлар составының белемен күтәрү курсларын (Мәскәү, 1952) тәмамлый. Новороссийск аэродингез клубында инструктор булып эшли. 1938 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 36 нчы гв. бомбардировщиклар авиациясе полкы эскадрильясенең элемтә башлыгы (2 нче һава армиясенең 202 нче бомбардировщиклар авиациясе дивизиясе). 1944 нең февраленә 1 нче Украина фронты эскадрильясе составында разведка һәм дошман коммуникацияләрен бомбага тоту максатында 182 сугышчан очыш ясый. Шәхсән 3 самолётны бәреп төшерә, төркемдәге самолётлар һәм җир өсте радиостанцияләре б-н ышанычлы элемтә урнаштыра. 1961 дән запаста, Казанда яши. Ленин ордены, Кызыл Байрак, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ШАПОВА́ЛОВ** Алексей Григорьевич (17.03.1909, Курск өлкәсенең Волуйки р-ны Волоконовка а. — 3.6.1965, Яшел Үзән ш.), корабльләр төзүче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1949). Мәскәү механика-машина төзелеше ин-тын тәмамлый (1937). 1937–51 елларда Яшел Үзән суднолар төзү з-дында эшли: инженер-технолог, баш технолог бүлеге төркеме җитәкчесе, баш технолог урынбасары — баш эретеп ябыштыручы. 1951–65 тә Яшел Үзән проектлау-конструкторлык бюросында: технол. бүлек җитәкчесе, баш конструктор урынбасары. Дәүләт бүләге корабльләр төзүнең агымлы алымын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШАПУКО́В** Борис Никитович (15.2.1937, Алабуга ш. — 13.2.2007, Казан), математик, геометр, физика-матем. фән. д-ры (1991), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), шунда ук эшли, геом. каф. мөдире (1993–2007). Хезмәтләре катламланган фәзалар геометриясенә карый. Ш. структураларны тикшерү алымнарын үстерә һәм катламланган күптөрлелекләрдә Ли дифферентлаштыру аппаратын төзи; алынган нәтиҗәләрне аналитик механикага һәм нәевклид фәзалары геометриясе мәсьәләләрендә куллануны тикшерә. Н.И. Лобачевский исем. халыкара геом. семинарларны оештыру ком-ты рәисе (1995, 1997, 2002), Н.И. Лобачевский исем. медаль бирү буенча халыкара бәйгеләрдә жюри рәисе (1997, 2002).

Х е з м.: Связности на дифференцируемых расслоениях // Итоги науки и техники. Сер. Проблемы геометрии. 1983. Т. 15; Задачи по группам Ли. К., 1989; Задачи по группам Ли и их приложениям. М., 2002; Производная Ли на расслоённых многообразиях // Итоги науки и техники. Сер. Соврем. математика и её приложения. 2002. Т. 73.

**ШАПШИ́Н** Михаил Исакович (6.12.1924, хәзер Белоруссия Респ-касы, Гомель өлкәсе Баевка а. — 20.2.1986, Казан), химик, химия фән. д-ры (1976), проф. (1979). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1953), шунда ук эшли. Хезмәтләре азоторганик кушылмалар химиясенә карый. Ш. күптөшле ароматик аминнар нитрочыгарылмаларын тикшерә. Каты шартлагыч матдәләрне сәнәгый җитештерүгә нигез булган каталитик ариламинлау реакциясен ача. Махсус химиягә багышланган 40 мәкалә авторы. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә ике Ватан сугышы ордены; медальләр б-н бүләкләнә.

**ШАРА́Й** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 37 *км* көньяктарак, Ваешур елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 33 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оешкан коненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Баулы волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1926 да — 80, 1938 дә — 126, 1949 да — 123, 1958 дә — 151, 1970 тә — 168, 1979 да — 89, 1989 да — 57, 2002 дә — 39 кеше.

**ШАРА́Н РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* көнбатышында урнашкан. 1935 елның 31 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 1384 $км^2$. Үзәге — Шаран авылы (Уфадан 201 *км* көнбатыштарак). Халкы — 20518 кеше (2017). Татарлар саны: 1970 тә — 13036, 1979 да — 8114, 1989 да — 12160, 2002 дә — 6675 кеше (татарлар санының кискен кимүе — БРда яшәүче татарларның хокукларын кысу сәясәте б-н бәйле рәвештә, 1979 һәм 2002 еллардагы халык санын алу мәгълүматларын бозып күрсәтү нәтиҗәсе). Ш.р.нда 108 торак пункт, ш.и. 47 татар, 3 башкорт-татар һәм 3 татар-чуаш, 2 рус-татар һәм 1 мари-татар авылы исәпләнә. Иң зур татар авыллары (2009): Шаран (5539), Зирекле (939), Түбәнге Зәет (779), Чалмалы (589), Түбәнге Ташлы (571). Иң борынгылары: Яңа Таулар (1632), Иске Теләүле (1702), Алпай (1742), Нөрәй (1762 дән билгеле) авыллары. Иң беренче булып татарлар Ярәмкә (1728), Чалмалы (1730 еллар), Иске Тамьян (1735 кә кадәр), Татар Көчеге, Сарсаз, Чәкәнтамак (1742), Түбәнге Зәет (1749), Тархан, Күгәрченбүләк (18 йөз уртасы), Үлкеьелга, Бурсык (1762 гә кадәр), Зирекле (1773 кә кадәр), Дүрмән һәм Югары Ташлы (1782) авылларында төпләнә. Ш.р.нда Башкортстан татарлары конгрессы район башкарма ком-ты, Татар иҗтимагый үзәгенең Шаран ф-лы; «Сөмбел» татар халык вокаль ансамбле һәм «Балкыш» драма коллективы (Шаран а.), «Ахирәтләр» вокаль ансамбле (Базгыя а.) эшли. 2015/16 уку елында Ш.р.ның 8 мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татар һәм рус телләрендә «Шаран киңлекләре» — «Шаранские просторы» район г-талары нәшер ителә. Язучылар И.Ә.*Абдуллин* һәм З.Һ.*Һадиның*, җырчы Ф.Г.*Вәлиәхмәтовның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ш.р. б-н бәйле.

**ШАРА́ПОВ** Сергей Иванович (18.7.1927, Киров өлкәсенең Санчурск р-ны Орловский а. — 29.10.2003, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1978), проф. (1981), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1985). Казан ун-тын тәмамлый (1956). 1956–59 елларда КПССның Казан шәһәре Молотов район ком-тында эшли. 1962 дән Казан ун-тында, 1978–2003 тә Казан техник ун-тында, икътисад теориясе һәм хокук каф. мөдире (2000 гә кадәр). 1978–82 дә Куба Респ-касында командировкада: совет белгечләре төркеме җи-

тәкчесе. Гавана югары пед. ин-ты ректорының һәм политэкономия каф. мөдиренең киңәшчесе. Хезмәтләре җитештерү чараларын җәмгатьләштерү, хезмәтнең иҗтимагый бүленеше, җитештерүне специальләштерү, нәтиҗәлелеген күтәрү һәм икътисади үсеш мәсьәләләренә карый. Япония б-н сугышта катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вопросы специализации и кооперирования промышленности. К., 1964; Разделение труда и развитие его форм в промышленности (Вопросы теории и методологии). К., 1974; Социально-экономические проблемы труда // Труд и его эффективность. К., 1976.

*Әд.:* Мазитова Р.К. Мальчик из Орловской — учёный с мировым именем // Теория и практика институциональных изменений в экономическом развитии общества: Сб. материалов междунар. науч.-практ. конф. К., 2009.

*А.Ш.Хәсәнова.*

**ШАРГИ́Н** Вячеслав Павлович (22.9.1957, Удмурт АССР, Ижевск), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002). Ижевск индустриаль техникумын (1976), Мәскәү авиация ин-тын (1985) тәмамлый. 1985 елдан «Казан вертолёт заводы» АҖдә: инженер-конструктор, бюро башлыгы, әйдәп баручы конструктор, бүлекнең баш конструкторы урынбасары (1994 елдан), АҖнең баш конструкторы идарәсе җитәкчесе урынбасары, серияле-конструкторлык бүлеге башлыгы (2007 дән). Дәүләт бүләге яңартылган Ми-8МТВ-1, Ми-8МТВ-2, Ми-8МТВ-3, Ми-8МТВ-5, Ми-172 вертолётларын һәм аларның модификацияләрен серияле җитештерүгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ША́РИКОВ** Геннадий Нестерович (22.12.1953, Әлмәт р-ны Ямаш а.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000), ТРның атказ. нефтьчесе (1994). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), «Татнефть» АҖдә эшли (бүленеп): «Елховнефть» НГДУда оператор, мастер, өлкән технолог, цехның өлкән инженеры, «Зәйнефть» НГДУда цех башлыгы, баш инженер, башлык (1999 елдан), «Прикамнефть» НГДУ башлыгы (2007 дән). 2006–07 дә «Татнефть-Алабуга» ҖЧҖ директоры. Дәүләт бүләге штанглы тирәннән суырту насослы җайланмаларның эшләү ышанычлылыгын арттыру буенча техник чаралар һәм технологияләр комплексын эшләүдә һәм сәнәгатьтә киң кулланугa кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШАРЛА́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Чирмешән елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 19,3 *км*, шуның 7,1 *км* озынлыктагы югары агымы ТР чикләрендә. Бассейнының мәйданы 121,3 *км*². Бөгелмә платосыннан ага. Елга башы Лениногорск р-ны Мичурин посёлогыннан 4 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 215 *м*, тамагыныкы — 118 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. Ш.ның 2 дән 6,7 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,27 *км/км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 110 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,08 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Ш. бассейнында суының гомуми күләме 0,6 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШАРЛАМА́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Урсалы елгасы буенда. 2010 елда 188 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб, китапханә. 18 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.да мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 672 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1746 да — 246 ир-ат; 1795 тә — 95, 1859 да — 152, 1889 да — 244, 1897 дә — 319, 1910 да — 408, 1920 дә — 429, 1926 да — 385, 1938 дә — 401, 1949 да — 383, 1958 дә — 354, 1970 тә — 431, 1979 да — 320, 1989 да — 196, 2002 дә — 204 кеше. Ш.да «Татнефть» АҖнең ген. директоры Р.Г.*Галиев* туган.

**ШАРЛЫ́К РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* төньягында урнашкан. 1924 елның 30 маенда оештырыла. Мәйданы — 2900 *км*². Үзәге — Шарлык авылы (Оренбургтан 150 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 16598 кеше (2017). 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 4101 кеше. Татарлар, тупланып, Яңа Муса (2010 да — 926 кеше), Сарманай (830), Мостафа (470), Шарлык (409), Йөзәй (291), Ялчекәй (240), Үрнәк (187), Зирекле авылларында яшиләр. Ш.р. терр-ясенә алар 18 йөзнең 40 елларында Яңа Мәскәү юлы тирәсендәге җирләрне үзләштерү б-н бәйле рәвештә урнаша башлый. 1744 тә Казан губернасының Казан һәм Зөя өязләреннән килүче татарлар — Мостафа, Сарманай, Йөзәй авылларына, 18 йөзнең 2 нче яртысында Башкортстаннан күченүче татарлар — Зирекле авылына, 1795 тә Сарманай авылыннан килүчеләр Яңа Муса авылына нигез сала. 20 йөз башында Мостафа авылында 2 мәчет (ш.и. таш мәчет, 1911), 2 мәдрәсә, Сарманай һәм Йөзәйдә 1 әр мәчет һәм мәдрәсә була. Ш.р.нда татар үзешчән коллективлары: «Радуга», «Солнышко» һәм «Чулпан» (Мостафа а.), «Сандугач» һәм «Чишмә» (Яңа Муса а.), «Сарман» (Сарманай а.), «Ләйсән» (Йөзәй а.), «Сандугач» (Ялчекәй а.) вокаль төркемнәре; «Күбәләк» (Яңа Муса а.), «Музыкальный сундук» (Сарманай а.), «Йолдыз» (Үрнәк а.) балалар ансамбльләре; «Бишбармак» (Мостафа а.), «Вәсилә» (Яңа Муса а.), «Маска» (Йөзәй а.) театр коллективлары; «Шатлык» фольклор ансамбле (Ялчекәй а.), «Ләйсән» хореография ансамбле (Мостафа а.) эшли. Мостафа авылы мәктәбенең 1–11 сыйныфларында, Сарманай һәм Яңа Муса авыллары мәктәбенең башлангыч һәм урта сыйныфларында татар теле фән буларак өйрәнелә. Мостафа (1994 тән), Яңа Муса (2000), Йөзәй (2001) авылларында мәчет эшли. Мостафа — шагыйрь М.М.*Җәлилнең* туган авылы (1919 да ул анда «Кызыл чәчәк» балалар оешмасын нигезли), 1976 да шагыйрь истәлегенә багышлап мемориаль музей ачыла. Ш.р.нда актёр Х.Г.*Әбҗәлилов*, Сов.Союзы Геройлары Р.Х.*Абдершин* һәм Н.М.*Галиев* туган.

**ШАРМА́НКА** елгасы, Идел алдында, Идел елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 16,5 *км*. Бассейнының мәйданы 161,4 *км*². Идел буе калкулыгыннан, Кама Тамагы р-нында ага. Елга башы Ясная Звезда авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак һәм Якты Алан авылыннан 3 *км* көнбатыштарак урман массивында, тамагы Тәмте авылыннан көнчыгыштарак. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычының терәү сулары астында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Нигездә, урманнар ерымнарда, Ш. һәм аның кушылдыкларының текә сөзәклекләрендә сакланган. Елганың 1,2 дән 11,5 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар, иң зурлары: Чирмеш (Черемиска) (9,3 *км*), Морковка (10,3 *км*) — уң, Мордвасу (11,5 *км*) — сул кушылдык. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,055 *м*³*/с*. Җәен суы иң аз вакытта елганың аерым урыннары кибә. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ШАРМА́Ш** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 9 *км* көньяктарак, Мишә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 340 кеше (руслар) яши. Мебель ф-касы, кирпеч з-ды. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Чиркәү. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә билгеле. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Введение чиркәве (1840 та төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1868 дә төзелә), ашлык саклау-сату кибете, су тегермәне, тимерче алачыгы, вак кредит учреждениесе, 1 казна шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1697 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Клю-



В.И. Шарпатов.

чище волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 90 ир-ат; 1859 да — 630, 1897 дә — 787, 1908 дә — 939, 1920 дә — 998, 1926 да — 985, 1938 дә — 865, 1949 да — 600, 1958 дә — 568, 1970 тә — 485, 1979 да — 431, 1989 да — 350, 2002 дә — 384 кеше.

**ШАРНИ́Н** Генрих Павлович (12.4.1931, Пермь ш. — 8.4.2018, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1967), проф. (1967), ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1975,1984), Казан технол. ун-тының атказ. профессоры (2007). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), шунда ук эшли (2010 га кадәр, бүлеп, 1982–97 дә Казан химия фәнни-тикшеренү ин-ты директоры), 1969–82 дә органик азот кушылмалары химиясе һәм технологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре ароматик рәттәге нитрочыгарылмалар химиясенә һәм технологиясенә карый. Ш. — утка чыдам шартлагыч матдәләр (УЧШМ) өлкәсендә гыйльми юнәлешкә нигез салучы. УЧШМне җитештерүнең теоретик нигезләрен эшли, утка чыдамлыкның молекулалар төзелешенә бәйлелеген ача. УЧШМне карбо- һәм гетероциклик күптөшле ароматик кушылмаларны синтезлау юлы б-н барлыкка китерү мөмкинлеген күрсәтә, бу класс кушылмаларның электрофил һәм нуклеофил алмашу реакцияләрендәге реакция ихтималын тикшерә, чыдамлык җәһәтенчә уникаль үзлекләргә ия матдәләр синтезын башкара. Ш. җитәкчелегендә тишү-шартлату эшләре өчен эшләнмәләр һәм аппаратура, кешене агрессив һәм токсик матдәләрдән, ионлы нурланыштан, янгын вакытындагы һәлакәтчел факторлардан саклаучы комплекслы чаралар эшләнә. Фәнни эшчәнлекнең нәтиҗәләре Чапаевск химия з-дында (Самара өлкәсе), илнең газ һәм нефть табу сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 275 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. РСФСР югары белем бирү министрлыгының координацион методик советы секциясе (1977–82), СССР ФА янындагы махсус продуктлар дәүләт комиссиясе (1975–82), СССР химия сәнәгате министрлыгы янындагы махсус комиссия (1983–90) рәисе. СССР Министрлар Советы бүләге (1985), ТР Дәүләт бүләге (1997) лауреаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын һәм бер көмеш медальләре; ТАССР Югары Советы мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Биогр. справ. К., 2009.

**ША́РНИН** Леонид Михайлович (18.8.1940, Мари АССРның Сернур р-ны Шарнино а.), информатика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1994), проф. (1997), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2002). 1968 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, техник кибернетика һәм информатика ф-ты деканы (1997–2007), бер үк вакытта, 1998 дән, мәгълүмат эшкәртү һәм идарә итүнең автоматлаштырылган системалары каф. мөдире, проректор (2002 гә кадәр). Хезмәтләре мәгълүматны чагылдыручы борт системаларын төзүнең алымнары һәм чараларына, техник югары уку йортларында мәгълүматлаштыру мәсьәләләренә карый. Ш. очу аппаратлары бортында уза торган мәгълүматлаштыру процессларын тикшерә; «очкыч-кеше-мохит» матем. моделен, очу аппаратларының экран индикациясе системаларын эргономик тикшерү өчен ике машиналы җир өсте сынау комплексын булдыра; экран индикаторларында сурәтләрнең динамик элементларын төзү алымнарын, ТУ-204, ИЛ-96/300 очкычлары өчен борт экраны индикаторын (серияле җитештерүгә кертелгән) эшли. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар (5 се сәнәгатьтә гамәлгә кертелгән). СССР ВДНХның ике көмеш һәм ике бронза медале, СССР Космонавтика федерациясенең М.С.Рязанский исем., СССР ФАнең А.Н. Туполев исем. медальләре һ.б. медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Математическая модель синтеза первичных изображений на растровом индикаторе // Автоматизация научных исследований. Куйбышев, 1987 (автордаш); Пространство и частотно-разнесённая фазовая система слепой посадки самолётов // Вестн. Казан. техн. ун-та. 1997. № 3 (автордаш); Оптимизация информационных характеристик измерительных каналов ИИС // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2005. № 3.

**ШАРПА́ТОВ** Владимир Ильич (21.3.1940, Мари АССРның Звенигово р-ны Красногорский пос.), РФ Герое (22.8.1996), очучы. Казан авиация ин-тының 3 курсын (1962), Красный Кут гражданнар авиациясе очучылар уч-щесен (1965), Гражданнар авиациясе академиясен (1976) тәмамлый. 1965–93 елларда Төмән шәһәре аэропортында, 1994 тән «Аэростан» (Казан) авиакомпаниясендә очучы булып эшли. 1995 нең 3 августында Ш. җитәкчелегендәге Ил-76 самолёты экипажы Тирана шәһәреннән (Албания Респ-касы) Кабулга (Әфганстан Респ-касы) рейс ясый. Очыш вакытында самолёт «Талибан» хәрәкәте истребительләре тарафыннан кулга төшерелә һәм Кандагар шәһәре (Әфганстан Респ-касы) аэропортында мәҗбүри утыртыла. Самолёт экипажы 378 көн әсирлектә була. 1996 ның 16 августында Ш. әсирлектән котылганда батырлык күрсәтә: Россия очучылары, сакчыларны коралсызландырып, самолётны һавага күтәрәләр һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә юнәлеш тоталар. 2010 елда төшерелгән «Кандагар» нәфис фильмында (реж. А.О.Кавун) экипажның әсирлектән качуы күрсәтелә. Әсирлектән кайткач, Ш. «Аэростан» компаниясендә эшләвен дәвам итә. 1999 дан Төмән шәһәрендә яши. 1999–2001 дә — «Төмәнавиа» авиакомпаниясендә Ил-76 самолёты очучысы. 2002 дән пенсиядә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШАРТЛАВЫ́К ЧӘЧӘ́К** (Silene), канәферчәләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел, сирәк кенә куакчыл үсемлекләр ыругы. 500 гә якын төре билгеле, нигездә,Төньяк ярымшарның уртача һәм субтропик поясларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 13 төре бар. Салынкы Ш.ч. (S. nutans), татар Ш.ч.ге (S. tatarica), яшел Ш.ч. (S. chlorantha), ябышкак Ш.ч. (S. viscosa) һ.б. барлык районнарда да очрыйлар. Болыннарда, тау битләрендә, нарат урманнарында, күп кенә төрләре бөртекле культуралар арасында чүп үләннәре буларак үсәләр. 10–90 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры торучан яки күтәрелмә, тармаклы, ябышкак. Яфраклары кыяк, ланцетсыман, бөтен. Чәчәкләре бер яки ике өйле, алсу, кызыл төстәге ике бүлемтеле, күп бүлемтеле яки бөтен таҗ яфракчыклы. Җимеше тартмачык. Июнь–июльдә чәчәк аталар. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (ботаклардан) үрчиләр. Ябышкак Ш.ч. һәм салынкы Ш.ч. халык медицинасында кулланыла: җир өсте өлешләрендә алкалоид, сапонин, флавоноидлар, С витамины бар; үләне тынәтмәсе йөрәк эшчәнлеге җитәрлек булмаганда, бөер авырулары вакытында файдаланыла. Күп кенә төрләре декоратив, баллы үсемлекләр.

**ШАРШАДЫ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 61 *км* көньяктарак, Иж елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 339 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1813 тә Сарапул өязенең Юрьино һәм Собачкино авылларыннан күченүче руслар нигез сала. 1840 елларда алпавыт Тәфкилевләр Ш. җирләренең үзләренеке булуын белдерә, һәм бу 1852 дә Дәүләт советы карары б-н беркетелә. 1853 тә рус крәстияннәре авылдан җибәрелә (к. *Рус Шаршадысы*), Тәфкилевләр үзләренең татар крепостнойларын урнаштыра; алар игенчелек, терлекчелек, такта яру һәм чыпта сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.да мәчет (1891 дә төзелә; архит-ра истәлеге), мәктәп, тегермән, скипидар з-ды, пристань эшли. 1906 да рус-татар земство мәктәбе ачыла. 1913 тә Тәфкилевләр утарында язучы Г.*Исхакый* кунак була. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Пьяный Бор волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 183, 1887 дә — 285, 1905 тә — 384, 1920 дә — 585, 1926 да — 645, 1938 дә — 658, 1949 да — 821, 1958 дә — 638, 1970 тә — 560, 1989 да — 401, 2002 дә — 367 кеше.

*Әд.:* М ә р д а н о в Р.Ф., Һ а д и е в И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**ШАТА́ЕВ** Владимир Георгиевич (27.4.1929, Владимир губ. Меленки ш.), очкычлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1980), проф. (1982), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1989). 1953 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, очу аппаратларының төзелеш механикасы каф. профессоры (1981–83), очу аппаратларын конструкцияләү һәм проектлау каф. мөдире (1983 тән), каф. профессоры (1996 дан). Хезмәтләре очу аппаратлары конструкциясенең ныклыгын хисаплау алымнарына карый. Ш. интенсив җылыну һәм шуышучанлык шартларында, көчәнешләр б-н деформацияләр арасында нәсызыкча бәйләнеш булган хәлдә юка диварлы авиаконструкцияләрне (канат, канатчыклар, корпус) хисаплау алымнарын, махсус кулланышлы очу аппаратлары ясаганда файдаланылучы программалар эшли. Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең атказ. югары белем бирү хезмәткәре (2008).

Х е з м.: К расчёту цилиндрических тонкостенных балок в физически нелинейной постановке // Изв. вузов. Авиац. техника. 1969. № 4; К расчёту на прочность тонкостенного корпуса на основе дискретно-континуальной модели // Изв. вузов. Авиац. техника. 1983. № 2 (автордаш); Конструкция самолётов: Учеб. для вузов. К., 1999 (автордаш).

**ШАТИ́ЛОВ** Владимир Михайлович (12.7.1952, Кыргызстан ССРның Талас р-ны Ивано-Алексеевка а.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), «Түбәнкаманефтехим» АҖдә эшли: мастер, смена башлыгы, инженер-технолог, цех башлыгы, этилен з-ды баш инженеры урынбасары, баш инженеры (1992 дән). Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге түбән олифеннар, бутадион һәм бензол җитештерү нәтиҗәлелеген һәм куәтен арттыру буенча эшләр комплексының фәнни һәм практик нигезләрен эшләүдә һәм аларны җитештерүгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШАТРО́В РАЙОНЫ́**, *Курган өлкәсенең* төньягында урнашкан. 1923 елның 10 декабрендә оештырыла. Мәйданы — 3535 *км*². Үзәге — Шатров авылы (Курган шәһәреннән 180 *км* төньяктарак). Халкы — 16024 кеше (2017). 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 1127 кеше. Алар, тупланып, 1718 дә нигезләнгән Кызылбай авылында (2012 дә — 845 кеше) яшиләр. 1800 дә анда мәчет ачыла (1915 тәге янгында яна; 2005 тә яңадан төзелә). Кызылбай авылы мәктәбендә 1920 — 68 дә укыту татар телендә бара, 1969 дан татар теле фән буларак өйрәнелә. Авыл мәктәбе каршында «Ярсу» фольклор коллективы (1990 нан), «Изге ай» вокаль коллективы (1993 тән), «Болан» балалар фольклор төркеме (1995 тән) эшли.

**ШАТУНИ́ХА КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Яшел Үзән р-ны Бело-Безводный авылыннан 0,7 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Идел елгасының югары террасасында, Сумка елгасы бассейнының уңъяк яр өлешендә урнашкан. Идел-Кама саклаулыгына керә. Су өслегенең мәйданы 1,2 *га*. Су күләме 22,8 мең *м*³. Озынлыгы 260 *м*, иң зур киңлеге 85 *м*. Уртача тирәнлеге 1,9 *м*, иң зур тирәнлеге 2,6 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Озынча түгәрәк формада. Ярлары сөзәк, урыны-урыны б-н таллар үсә. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, йомшак (1,8 *мг-экв/л*), коңгырт-сары төстә. Үтә күренмәлелеге 0,2–0,6 *м*.



Шатуниха күле.

**ШАТУНО́ВА** Татьяна Михайловна (7.10.1956, Казан), философ, филос. фән. д-ры (2009), проф. (2013). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1979), шунда ук филос. кафедрасында эшли. 2007 елдан социаль филос. һәм культурология, 2011 дән социаль филос. кафедрасында. Хезмәтләре социаль филос., шәхес проблемаларына, культура теориясе һәм философиясенә, постмодерн философиясе мәсьәләләренә карый. РФнең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2004).

Х е з м.: Постмодерн как ситуация философствования. СПб., 2003 (автордаш); Социальный смысл онтологии эстетического (опыт оправдания красотой). К., 2007; Эстетика социального (эстетическое начало в процессе идентификации современного человека): Учеб. пособие. К., 2012.

**ШАФРА́НОВ** Пётр Григорьевич (22.1.1901, Казан губ., Тәтеш өязе Зур Фролово а. — 4.11.1972, Мәскәү), генерал-полковник (1958), Сов. Союзы Герое (19.4.1945). Ф.Э.Дзержинский исем. артиллерия академиясен тәмамлый (Мәскәү, 1934). 1919 елдан Кызыл Армиядә. Гражданнар сугышында катнаша; Көньяк фронтта барон П.Н.Врангельнең ак армиясенә каршы сугыша. 1923–38 дә Кызыл Армиянең артиллерия подразделениеләрендә командирлык вазифаларында. 1938–41 дә СССР ХКС каршындагы Оборона ком-тында. Бөек Ватан сугышы вакытында 249 нчы укчы дивизиянең артиллерия командиры (полковник), 1942 дән Калинин, Брянск, 1 нче Балтыйк буе фронтларында 16 нчы гв. укчы дивизиясе һәм 36 гв. корпусы командиры (генерал-майор), 1944 тән 3 нче Белоруссия һәм 1 нче Украина фронтлары составында 5 нче һәм 31 нче армияләр командующие (генерал-лейтенант). Сугыштан соң 31 нче армия б-н җитәкчелек итә, 1948 дән Донбасс, Баку, Урал һава һөҗүменнән саклану р-ннары гаскәрләре командующие, 1956 дан Хәрби-командирлар академиясе башлыгы. 1959–66 да Варшава договорында катнашучы илләрнең Берләшкән кораллы көчләре штабында. 1950–54 тә СССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, өч Кызыл Байрак , 2 нче дәрәҗә Суворов, 2 нче дәрәҗә Кутузов, 2 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий орденнары, медальләр, чит дәүләтләр бүләкләре б-н бүләкләнә. Буа шәһәренең Дан скверында Ш. бюсты куелган; туган авылында һәм Буада урамнар Герой исемен йөртә.



П.Г. Шафранов.

*Әд.:* Великая Отечественная война 1941–1945: Энцикл. М., 1985; Великая Отечественная. Командармы: Военный биогр. словарь. М., 2005.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ШАХМА́Й** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 14 *км* көнбатыштарак, Чаллы елгасы (Чишмәнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 538 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шехмай исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашман хезмәтен үти; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 1870 тә төзелгән 2 мәчет (берсе 1нче мәхәлләнеке, икенчесе 2 нче мәхәлләнеке; 1922 дә яңартып салына; архит-ра истәлеге), 2 җил тегермәне, 11 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4922 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Каргалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 187 ир-ат; 1859 да — 1526, 1897 дә — 2120, 1908 дә — 1920, 1920 дә — 2022, 1926 да — 1777, 1938 дә — 1353, 1949 да — 635, 1958 дә — 790, 1970 тә — 826, 1979 да — 671, 1989 да — 603, 2002 дә — 594 кеше.

**ША́ХМАТ** (фарсы. شاهمات — шах мат — хаким үлде), ике көндәш өчен 64 шакмаклы тактада махсус фигуралар б-н логик өстәл уены. Хәзерге Татарстан терр-ясендә 11–12 йөзләрдән билгеле. 1884 елда Казанда «Шахмат уенын сөючеләр җәмгыяте» шахмат клубы ачыла (1884 тә раслана). Респ-каның беренче чемпионаты 1920 дә уздырыла (чемпион М.М.Сегель). Ш. 1920 йөз башыннан киң таралыш ала. ТР шахматчыларының Казан командалары Россия (1995, 1996 — көмеш; 1998, 2002–03, 2005, 2015 — бронза — ирләр), (2003, 2007, 2012, 2014 — бронза — хатын-кызлар), Европа (1996, 1998 һәм 2004 — бронза; 2006 — көмеш — ирләр), (2003 — бронза — хатын-кызлар) клуб чемпионатларында җиңүчеләр (призёрлар). 2018 гә Татарстанда Ш. 22 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләрендә: Казанда (5 мәктәп, ш.и. Р.Г.Нәҗметдинов исем. Олимпия резервындагы үзәк махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр шах-



Г.Н.Шаһвәлиев.

мат мәктәбе, 1975 тә ачыла, 1988 дән хәзерге исемдә; «Тасма» Олимпия резервындагы махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе), Түбән Камада (2), Чистайда (2), Бөгелмәдә (1), Баулыда (2), Яшел Үзәндә (1), Чаллыда («Этюд» — 1976 да ачыла, 2008 дән хәзерге исемдә), Лениногорскида (1), Алабугада (1), Азнакайда (1), Буада (1), Менделеевта (1), Васильево штп да (1), Биектау (1), Югары Ослан (1) авылларында җәелдерелә; 6 яшүсмерләр клубы һәм 4 мәктәптән тыш эшләр һәм балаларга өстәмә белем бирү үзәге (Казанда); спорт-сәламәтләндерү комплексларында 4 Ш. бүлеге — Казанда (1), Түбән Камада (1), Лаешта (1), Актүбә штп да (1). Татарстанның иң яхшы шахматчылары (спортчылар, тренерлар): К.Л.Амбарцумова, Л.В.Волошин, А.М.*Галләмова*,



Р.Г.Нәҗметдинов исем. Олимпия резервы үзәк махсус балалар-яшүсмерләр шахмат мәктәбе бинасы.

В.И.*Гончаров*, Т.В.Грабузова, Е.Е.Заяц, И.Р.Ибраһимов, А.И.Ильин, С.В.Кузнецов, Ю.О.Машинская, Н.И.Мөхәммәтҗанов, Р.Г.*Нәҗметдинов*, А.Н.Панченко, С.В.Рублевский, А.В.Тимофеев, Е.Тимофеева, А.В.Харлов, Р.В.Хәсәнгатин, А.Шәрәфиев, С.С.Шәйдуллина, В.П.Яндемиров һ.б. 1979 дан ел саен Казанда Россия Ш. мәктәпләре укучылары арасында Р.Г.Нәҗметдинов истәлегенә турнир; 1997 дән Актанышта, 2007 дән Казанда А.М.Галләмова призына балалар мәгариф учреждениеләре, клублары, спорт мәктәпләре командаларының бөтенроссия турнирлары; 2004 тән Чаллыда Н.И.Мөхәммәтҗанова мемориалы (халыкара турнир) уздырыла. ТР Ш. федерациясе президенты — Г.Н.Захаров (2004 тән).

*Әд.:* К у з н е ц о в В.Г., М у с и н Б.М. Шахматные звёзды Татарстана. К., 2005.

**ША́ХМАТ ҺӘМ ША́ШКА САРАЙЛАРЫ́**, 1) Р.Г.Нәҗметдинов исем. респ-ка шахмат һәм шашка сарае, 1950 еллар ахырында Казанда Шахмат клубы буларак оештырыла (1988 дән Р.Г.Нәҗметдинов исем. Шахмат һәм шашка йорты, 1991 дән хәзерге исемдә). 1996 да ТРның Физик культура, спорт һәм туризм дәүләт ком-тының Олимпия резервындагы үзәк балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе б-н берләштерелә. Гомуми мәйданы 1447 *м*², файдалану мәйданы урыны 847 *м*², уку мәйданы 558,6 *м*². Бинасы: 10 уку класслары (ш.и. компьютерлар һәм гомуми физик әзерлек буенча спорт заллары), гомуми мәйданы 264,5 *м*², 196 уен урыны сыешлы 2 турнирлар залы. Казанда һәм Тәтештә ф-ллары бар. 2) Чаллыда Үзәк шахмат-шашка клубы (проектның авторы Б.Р.Рубаненко, 1987 дә файдалануга тапшырыла), 1995 кә кадәр — «КАМАЗ» шахмат-шашка клубы. Гомуми мәйданы 2500 *м*² булган бинада 8 уку классы, 2 турнирлар залы (468 *м*²), компьютерлар һәм мәгълүмат-белешмәләр үзәге, азык-төлек блогы бар. ТРның Ш.һ.ш.с. — Россия һәм чит илләрдә шахмат, шашка, го кебек интеллектуаль уеннарны пропагандалау һәм үстерү буенча уку-спорт үзәкләре буларак билгеле.

**ШАҺВӘЛИ́ЕВ** Галимҗан Нургаяз улы (23.12.1919, Казан губ., Спас өязе Татар Төгәлбае а. — 24.5.1982, Ярославль өлкәсенең Тутаев р-ны Варегово штп), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), ефрейтор. Ярославль өлкәсендә эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 44 нче моторлаштырылган понтон-күпер батальоны отделениесе командиры (46 нчы армиянең 2 нче понтон-күпер бригадасы). Дала, 2 нче һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Дебрецен (1944) һәм Прага (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 4 декабрендә Эрчи шәһәре янында (Венгрия) Дунай елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: катер тартып барган понтонда пехота һәм артиллериянең беренче десантын күчерә; икенче ярда барган сугышта катнаша, шәхсән кул пулемёты утын бастыра һәм дошманның 12 солдатын юк итә; яралана, әмма, хәрби техникалы 2 батальонны елга аша чыгарып, тагын 10 рейс ясый. Сугыштан соң демобилизацияләнә, 1946–79 да Варегово шәһәрендә торф пр-тиесендә эшли. Ленин ордены, 3 нче дәрәҗә Дан ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Мурманск шәһәрендә, инженер-сапёрлар полкы терр-ясендә Геройның бюсты куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ШАҺГАЛИ́ ХАН (ШӘЕХ ГАЛИ)** (1506 тирәсе — 20.4.1567, Касыйм ш.), Касыйм (1516–19, 1536–46, 1546–51, 1552–67) һәм Казан (1519–21, 1546, 1551–52) ханы. *Шәех Әулияр хан* улы. Атасы үлгәннән соң (1516), Касыйм ханлыгы тәхетенә утыра. 1519 елда Казан тәхетенә утыртыла. 1521 дә Казан аксөякләре аны тәхеттән төшергәч, Рус дәүләтенә кача. 1533–35 тә Казан б-н яшерен мөнәсәбәттә булу сәбәпле, рус хөкүмәте тарафыннан кыерсытыла, Белоозерога сөрелә. Берничә тапкыр Казан һәм Касыйм тәхетендә була, Мәскәү Казанга каршы оештырган сугыш хәрәкәтләрендә (1523–24, 1537, 1539, 1540); 1545–51 дә *Казанга Рус дәүләте яуларында* һәм *Казанның яулап алынуында* (1552) катнаша. Рус елъязмаларына караганда, рус гаскәренең Казан ханлыгына каршы сугышында таяну базасы хезмәтен үтәгән Зөя кальгасын төзү урыны Ш.х. киңәше б-н сайлана. Казанда соңгы тапкыр хөкемдарлык иткәндә (1551–52), Рус дәүләте тарафыннан басып алынган Тау ягын контроль астына алырга исәпли, әмма патша Иван IV бу ниятне кискен кире кага. Казан аксөякләрен җәберли. Иван IV таләбе буенча хан тәхетен ташлап китә, әмма Казанга рус гаскәрен керттерми. Татар чыганакларының берсендә Казаннан качар алдыннан Ш.х. сугыш кораллларын һәм кирәк-яракларын яраксыз хәлгә китерә: «туп көпшәләренә аккургаш коя, дарыга су сала». Соңыннан Ливониягә яуда (1557–58) рус гаскәрен җитәкли, Бөек Литва кенәзлегенә каршы сугышта катнаша (1562–65). Ш.х. хатыннарының берсе Казан идарәчесе *Сөембикә* була (1551 дә тәхеттән төшерелгәннән соң, Мәскәүгә җибәрелә, Ш.х.га көчләп кияүгә бирелә; кайбер мәгълүматларга караганда, Ш.х. Сөембикәгә начар мөгамәлә күрсәтә). Татар халкының тарихи хәтерендә Ш.х. тискәре төсмер ала. М.Г.Худяков язганча, ул «чит ил кешеләре кулында ихтыярсыз кол, Казанга исә бөтенләй ят була». Касыйм шәһәрендәге тәкиядә җирләнә (к. *Шаһгали хан тәкиясе*).

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863. Ч. 1.; Х у д я к о в М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; А л и ш е в С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995; История татар с древнейших времён. К., 2014. Т. 4.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ШАҺГАЛИ́ ХАН ТӘКИЯСЕ́**, Рязань өлкәсе Касыйм шәһәрендә Шаһгали хан төрбәсе, архит-ра истәлеге, Алтын Урда чорына хас, тулысынча диярлек сакланган бердәнбер күп бүлемле тәкия. 1555–56 елларда хан сарае янында төзелә. Керү юлы көньякта булган, хәзерге вакытта диварының тышы сакланмаган хәлдәге ике бүлемле таш корылма (13,5×8,5×5,0 *м*). Зур бүлем а́ркалы кечерәк 4 тәрәзә б-н яктыртылган, аның астында төрбә урнашкан. Төрбәгә тышкы яктан тәкиягә керү юлының уң ягындагы тар таш баскычтан төшеп булган. Коръән укый торган икенче бүлемгә Көнбатыш фасадтагы ишектән керелгән. Ул җир идәнле, бер тәрәзә б-н генә яктыртылган. Һәр бүлем кирпеч б-н көймәләп ябылган, аны фасад ягыннан



Касыйм шәһәрендәге Шаһгали хан тәкиясе. 1555–56. Хәзерге күренеше.

биек парапет каплап торган. Түбәнең әүвәлге эшләнеше билгеле түгел, хәзерге вакытта аның өсте туфрак б-н капланган. Түбәгә җыелган сулар парапетта урнаштырылган таш улаклардан агып төшә. Фасадлар яхшы эшкәртелгән дүртпочмаклы известьташ блоклардан өелгән. А́ркалы, биек булмаган ишек каймаларсыз ясалган. Төрбәгә керү юлында өстендә профильле куышлыкта гарәп хәрефләре б-н сөлес ысулында «Бу бинаны төзүче һәм хуҗасы — Шаһгали бине Шәех Әүлияр Солтан, 21 нче шәһре рамазан 962 нче сәнә» (григориан календаре буенча — 9 авг. (1555)) дип язылган. Куышлык өстендә ике кыеклы профильле кәрниз чыгып тора. Төрбәдә Шаһгали хан һәм аның гаилә әгъзаларыннан сигез кеше җирләнгән. Планы һәм төзү техникасы ягыннан бу корылма Болгар һәм Алтын Урда чоры шәһәрлекләрендәге кайбер төрбәләргә охшаш. Рязань тарих-архит-ра музей-тыюлыгы ф-лы составына керә.

*Әд.:* А х м е т з я н о в М.И. Татарские мавзолеи (дюрбе) в г. Касимове // Татарская археология. 2006. № 1/2 (16–17); Х а л и т о в Н.Х. К реконструкции архитектуры дворца в Хан-Кермене // Средневековые тюрко-татарские государства. К., 2009. Вып. 1.

**ШАҺГАЛИ́ЕВ** Фәрит Солтан улы (8.2.1947, Алтай крае Барнаул ш.), Сов. Союзы Герое (8.4.1982), хәрби очучы, авиация генерал-майоры (1993). ДОСААФ аэроклубын (Ташкент, 1965), ДОСААФның Аткарск уку-укыту авиация үзәген (Саратов өлкәсе, 1967), Сызрань очучылар югары Хәрби авиация уч-щесен (1973), Ю.А.Гагарин исем. Хәрби-һава академиясен (Мәскәү өлкәсенең шәһәр тибындагы Монино пос., 1987) тәмамлый. 1970 елдан СССР Кораллы Көчләрендә, Тын океан чик буе округында Сахалин утравында хезмәт итә, 1971 дән 14 нче аерым авиация эскадрильясенең вертолёт экипажы командиры, 1974 тән 15 нче авиация полкында звено командиры, очуга хәзерлек эскадрильясе командиры урынбасары. 1979 да Небит-Даг (Төрекмәнстан ССР) шәһәрендә Урта Азия чик буе округының аерым вертолёт эскадрильясендә очуга хәзерлек буенча командир урынбасары. 1979–83 тә Әфганстан Демократик Респ-касында Совет гаскәрләренең чикле контингенты составында, СССР КГБсы чик буе гаскәрләренең 23 нче аерым авиация вертолётлар эскадрильясе командиры. Әфганстан Респ-касы терр-ясендә Ми-8 һәм Ми-24 вертолётларында 1200 дән артык сугышчан очыш ясый; 1981 нең мартында тауларда бәреп төшерелгән совет самолёты экипажын таба һәм аны эвакуацияли; 1981 нең октябрендә чик буе гаскәрләренең хөкүмәткә каршы көчләр отряды тарафыннан чолгап алынган манёврлы төркемен алып чыга (80 кеше); СССРда беренче булып диңгез тигезлеге өстеннән 3500 *м* югарылыкта десант төшерә (шушы батырлыклары өчен Ш.ка Герой исеме бирелә). 1983–88 дә СССР КГБсы чик буе гаскәрләренең Баш идарәсендә (Мәскәү), инспектор-очучы, 1988 дән очышлар иминлеге хезмәте башлыгы. 1989–94 тә РФнең Таҗикстан Респ-касындагы чик буе авиациясе командующие. 1997 дән запаста, Мәскәүдә яши, «Камов» ҖЧҖнең ген. директоры ярдәмчесе булып эшли. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, «Шәхси батырлык өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

**ШАҺГӘРӘ́ЕВ** Зәкиҗан (1882, Самара губ., хәзер Азнакай р-ны Күк Тәкә а. — 1937 дән соң), дин эшлеклесе, язучы. Туган авылында имам булып хезмәт итә. «*Бубилар эше*»нә бәйле рәвештә пантюркизмда гаепләнеп кулга алына. «Төрмәләр хәтирәсе» (1913; 1994–95 тә «Мирас» ж-лында кабат басыла) документаль автобиографик повесте авторы. Анда авторның Бөгелмә, Минзәлә, Алабуга, Сарапул төрмәләрендә кичергәннәре чагыла, тоткынлык һәм ирек капма-каршы куела, авторның фәлсәфи уйланулары гарәп поэзиясе үрнәкләре, фольклор һәм авторның үз шигырьләре б-н үрелеп бара; табигать күренешләренә зур игътибар бирелә. Үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиогр. сүзлек. К., 2005.

**ШАҺИӘХМӘ́Д бине́ МӨХӘММӘ́Д әл-МӘҢГӘРИ́** (1860–1935 тирәсе), тарихчы, җәмәгать һәм дин эшлеклесе. Казан өязе Олы Мәңгәр авылы имам-хатибы. Олы Мәңгәр авылы халкының баш күтәрүенә багышланган «Вакыйгалар көзгесе» («Миръәтел-вөкугат») исемле кулъязмасы һәм Кышкар мәдрәсәсенә багышланган «Истәлек» («Тәзкирә», 1914), «Бәянелхак» (1898) хезмәтләре мәгълүм.

**ШАҺИӘХМӘ́Д бине́ ХӨСӘЕ́Н әс-СИМӘКИ́** (1787–8.4.1837, Оренбург губ., Минзәлә өязе Симәк а.), дин эшлеклесе. Г.И.*Курсави* шәкерте. Бохара шәһәрендә мәдрәсәдә укуын тәмамлаганнан соң, әүвәл Минзәлә өязенең Такталачык, соңыннан Симәк авылы мәчетендә имам-хатыйп һәм мәдрәсәдә мөдәррис була; ул җитәкләгән уку йортлары төбәктә мәгърифәт үзәкләре булып танылa. Мөселман хокукы-фикъһ буенча хезмәтләр авторы.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Асар. К., 2006. Т. 1.

**ШАҺИӘХМӘ́ТОВ** Әхмәдулла Кәлимулла улы (29.1.1923, Спас кантоны Иске Алпар а.), слесарь, Соц. Хезмәт Герое (1966). Хезмәт эшчәнлеген 1939 елда 22 нче Казан авиация з-дында башлый. 1947–92 дә Казан ТЭЦ-2 дә эшли. Герой исеме илнең энергетикасын үстерү буенча җидееллык планны үтәгәндә ирешелгән зур уңышлары өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Казан ТЭЦ-2 музеенда Геройга багышланган стенд бар.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ШАҺИӘХМӘ́ТОВ** Мәхмүт Шаһинур улы (1888, Уфа губ. Биштәк а. — 1972, Мәскәү), хәрби һәм сәяси эшлекле. «Госмания» мәдрәсәсен (Уфа ш., 1909), Көнчыгыш хезмәт ияләре коммунистик ун-тын (Мәскәү, 1931) тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша: 1914 елда 127 нче запас полкта взвод командиры. Эсерлар партиясенә иярә, сугышка каршы агитация алып барганы өчен рядовой дәрәҗәсенә төшерелә һәм Румыния фронтына җибәрелә. 1917–18 дә Уфада була, шәһәр советы әгъзасы, шәһәр хуҗалыгы комиссары. Кызыл Армия өчен татар-башкорт частьлары төзүдә катнаша. 1920 дә Татар запас батальоны командиры, Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясенең 9 нчы Казан совет кавалериясе Көнчыгыш халыклары команда составы курслары комиссары. ТАССР ҮБК әгъзасы. 1921 дә РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-ты каршындагы ТАССР вәкиллеге әгъзасы. 1922 дә Башкортстан АССР ҮБК әгъзасы. 1925–31 дә РСФСР БҮБК референты. 1931 дә репрессияләнә: «Крәстияннәр иттифагы» милләтче башкүтәрүчеләр оешмасында катнашуда гаепләнә һәм 3 елга төзәтү лагерена җибәрелә. 1936–38 дә Наманган шәһәрендә (Үзбәкстан ССР) мәдәният һәм ял паркы директоры. 1938 дә кабат кулга алына, 1939 да аклана; 1957 дә реабилитацияләнә. 1950 еллардан Мәскәүдә хуҗалык эшендә; татар җәмгыятенең актив эшлеклесе, Мәскәүдә татар мәктәпләре һәм балалар бакчалары ачуны яклап чыга. Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г и з з а т у л л и н И. Шагиахметов М.Ш. // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2; А с а б и н Е.П. Под знаменем революции. Уфа, 1991; Книга памяти жертв политических репрессий. К., 2006. Т. 16; Ислам на Урале: Энцикл. словарь. М.-Н.Новгород, 2009.



Ф.С.Шаһгалиев.



Ә.К.Шаһиәхмәтов.

**ШАҺИӘХМӘ́ТОВ** Мидхәт Рәфкать улы (5.11.1969, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. д-ры (2010). ТРның атказ. икътисадчысы (2006). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1991). 1990–93 елларда Дәүләт салым инспекциясенең Казанның Совет р-ны, 1993–94 тә Казан буенча салым инспекторы, 1994–96 да Дәүләт салым инспекциясенең Казанның Мәскәү р-ны буенча бүлек башлыгы. 1996–97 дә Казанның Мәскәү р-ны хакимияте башлыгы урынбасары. 1997–98 дә ТР Дәүләт милке б-н идарә итү ком-ты рәисе урынбасары. 1998–2007 дә Федераль салым хезмәтенең ТР буенча идарәсе җитәкчесенең 1 нче урынбасары, 2007–2009 да җитәкчесе. 2009–10 да ТР Премьер-министры ярдәмчесе. 2010 да ТР Президенты ярдәмчесе. 2010–14 тә ТР икътисад министры, 2014–17 дә Россия банкының Идел-Вятка баш идарәсе башлыгы урынбасары — ТР Милли банкы идарәчесе, 2017 дән — ТР Үзәк сайлау комиссиясе рәисе. Хезмәтләре базар икътисады шартларында кабаттан бүлү мөнәсәбәтләрен дәүләт та-



Б.Шаһиди.

рафыннан көйләү мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Государственное регулирование перераспределительных доходов. К., 2004; Современные аспекты развития перераспределительных отношений. К., 2008; Перераспределительные отношения в современной экономике России. М., 2009.

*Е.Б.Долгов.*

**ШАҺИӘХМӘ́ТОВ** Минһаҗ Шаһиәхмәт улы (1872–1941), эшче-рационализатор, Хезмәт Батыры (1928). Самара губернасының Мәләкәс шәһәрендә тукучылар профсоюзын оештыруда катнаша.

**ШАҺИДИ́** Борһан (3.10.1894, Сембер губ., Тәтеш өязе Аксу а. — 27.8.1989, Пекин, Кытай), Кытай сәясәт эшлеклесе. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә (Казан, 1909 елга кадәр), Берлин ун-тында (1930–33) белем ала. 1911–22 дә татар сәүдәгәрләре Габделҗаббаровларның «Тянь-Шань» сәүдә компаниясе хезмәткәре: 1912 дән Өремче шәһәрендәге Кытай ф-лында; бер үк вакытта, 1920–22 дә, таможня идарәсендә тәрҗемәче. 1922–25 тә атчылык фермасы идарәчесе. 1925–29 да Шөнҗан провинциясенең автомобиль ассоциациясе җитәкчесе. 1934 нең апрелендә Шөнҗан хезмәт ияләре съездында катнаша, анда аның тәкъдиме буенча провинциянең төп халкы исеме «уйгыр» рәвешендә раслана (аңарчы җирле халыкны кашгарлык, таранчы, сарт дип йөрткәннәр). 1937 дә Кытайның Зайсан шәһәрендәге (Казакъстан ССР) консулы. 1938 дә, гоминдан хөкүмәте Көнбатыш Кытайда массакүләм репрессияләр уздырганда, төрмәгә ябыла, анда 1944 кә кадәр тотыла; бер үк вакытта, провинция җитәкчеләренең рәсми документларын тәрҗемә итү вазифасын башкара. 1944–47 дә Өремче шәһәре губернаторы (вәли). 1947–48 дә Нанкин шәһәрендәге гоминдан хөкүмәте әгъзасы. 1949 дан Кытай Коммунистлар партиясе әгъзасы. 1955–66 да Бөтенкытай мөселманнары җәмгыяте рәисе, Кытай Халык сәяси консультатив советы рәисе урынбасары (Пекин). Кытай мәдәни рев-циясе елларында репрессияләнә, төрмәгә утыртыла (1966–78). «Уйгырча-кытайча-русча сүзлек» (Пекин, 1953); «Шөнҗанда илле еллык тормышым» (1984) исемле автобиографик әсәр (1984) авторы (кытай телендә язылып, уйгыр (Пекин, 1985) һәм казакъ (Өремче, 1985) телләренә тәрҗемә ителә).



Борһан Шаһиди һәм Мао Цзэдун. 1950.

*Әд.:* Г о с м а н о в М. Ябылмаган китап, яки Чәчелгән орлыклар. К., 1996; Х а л и у л л и н Ю. Мир вокруг нас (научные записки дипломата). М., 2011.

*М.Г.Госманов.*

**ШАҺИДУ́ЛЛИН** Роальд Рифгать улы (5.8.1928, Әгерҗе р-ны Тирсә а. — 8.7.2013, Казан), химия физигы, химия фән. д-ры (1997), проф. (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1950), Казанда ВЛКСМның район һәм өлкә ком-тларында эшли. 1956 елдан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, спектр-структура тикшеренүләре лаб-ясе мөдире (1989 дан), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1996 дан). Хезмәтләре элементорганик кушылмалар спектроскопиясенә карый. Ш. тирбәнешле, оптик спектрларны һәм азот, фосфор, мышьяк, сөрмә органик кушылмаларының төзелешен тикшерә. Спектр-структура корреляцияләренең системаларын билгели. Оптик спектрларны шифрсызландыру, системалаштыру, хисаплауның, максатчан молекуляр структураларны прогнозлауның компьютерлаштырылган алымнарын тәкъдим итә. Фосфорорганик кушылмаларның инфракызыл спектрлары буенча өч махсуслаштырылган атласның, фосфор һәм мышьякның органик чыгарылмалары спектрлары турындагы белешмәлекләрнең автордашы. Тикшерү нәтиҗәләре медицинада, нефть химиясендә, экологиядә, сәнәгатьтә һәм а.х.нда файдаланыла. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт Билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Атлас ИК-спектров фосфорорганических соединений. М., 1977 (автордаш); Атлас ИК-спектров фосфорорганических соединений (Интерпретированные спектрограммы). М., 1984 (автордаш).

**ШАҺИДУ́ЛЛИН** Рөстәм Рифгать улы (30.1.1939, Минзәлә ш.), математик, физика-матем. фән. д-ры (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук хисаплау матем. кафедрасында эшли (бүленеп: 1972–80 елларда — СССР ФАнең Казан физика-техника ин-тында). Хезмәтләре метаматематикага, өзелешле агымнар гидромеханикасына, аэрогидросыгылмалыкка һәм йомшак сүрүләр теориясенә карый. Ш. йомшак сыгылмалы сүрү тигезләнешенең нәсызыкча тигезләмәләрен чишү ихтималын тикшерә; йомшак сүрүне тасвирлау өчен матем. модельләр тәкъдим итә, физик нисбәтләрнең мөмкин булган төрен өйрәнә; сыеклык агымы б-н сүрү арасындагы тигезләмәләрен тикшерү алымын, ш.у. сүрүнең ягалап агу модельләрен тәкъдим итә.

Х е з м.: Численный метод дискретных вихрей. К., 1986; Минимизация функционала полной энергии для мягкой оболочки // Изв. вузов. Математика. 1998. № 3; Проблемы математического моделирования мягких оболочек. К., 2001.

**ШАҺИДУ́ЛЛИН** Шәрәфетдин Кәшшафетдин улы (1870, башка мәгълүматлар буенча, 1879, Казан губ., Мамадыш өязе Шәмәк а. — 25.8.1942, Казан), нашир, китап сәүдәгәре. 19 йөз ахырында Иргиз шәһәрендә (хәзерге Казакъстан) татар язучысы Ф.Кәрими китапларын, 1899 елдан Оренбург шәһәрендә үз шәхси нәшрият компаниясендә — «Россия мөселманнары сәүдә-сәнәгать календаре»н, («Торгово-промышленный календарь мусульман России»), 1900 дә «Көнчыгыш Урал алды төбәге мөселманнарының сәүдә-сәнәгать адрес-календаре»н («Торгово-промышленный адрес-календарь мусульман Восточно-Приуральского края») чыгара. 1909 да Казанда Халыкара вак сәнәгатьчелек һәм һөнәри белем күргәзмәсе уздырылу уңаеннан татар һәм рус телләрендә «Безнең Казан» — «Казан шәһәренең күрсәткече һәм күргәзмәсе турында мәгълүматлар» («Указатель г.Казани и сведения о выставке») белешмәлеген әзерли һәм бастыра. Анда товарлар һәм хезмәтләр рекламалана, күргәзмәнең максаты һәм бурычлары бәян ителә. 1910 да Ш. Идел буе губерналары һәм шәһәрләре турында тәфсилле мәгълүмат бирелгән «Идел нәһерендә юлдаш» белешмәлеген бастыра. Аның мөхәррирлегендә Казанда татар һәм рус телләрендә «Игъланәт» («Объявление», 1909–10) г-тасы, «Русия сәүдәсе» («Торгово-промышленная Россия», 1914–17) ж-лы нәшер ителә. Ш. күп кенә җәдитчеләр б-н тыгыз хезмәттәшлектә була, «Заман» календаре битләрендә аларның идеяләрен пропагандалый. 1917 нең 23 мартында татар эшлеклеләре төркеме, ш.и. Ш. тарафыннан Мөселман нәшрият хезмәткәрләре җәмгыяте төзелә. Советлар вакытында дәүләт учреждениеләрендә эшли. Репрессияләнә, төрмәдә үлә; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* М и н н у л л и н а Л. Шарафутдин Шагидуллин — издатель и редактор // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2002. № 1/2.

**ШАҺИДУ́ЛЛИНА** Мөнирә Габдулла кызы (13.11.1923, Казан — 13.9.2001, шунда ук), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1973). 1946–86 елларда Татар респ-ка күч-



М.Г. Ш а һ и д у л л и н а Миңнури ролендә («Бөркетләр кыяга оялый», И.Юзеев; сулда – М.Хәмзин).



М.Г.Шаһидуллина.

мә театрында (хәзер Татар драма һәм комедия театры) эшли. Сәхнәгә ятышлы сылу кыяфәте, матур тавышы, мөлаемлыгы һәм лирик сәләте Ш.ны труппаның әйдәп баручы актрисасы итә. Галина («Йөрәк давыллары», З.Шаһиморат), Галия («Тапшырылмаган хатлар», Г.Кутуй) кебек драматик рольләр башкарып, Ш. тамашачы игътибарына героиняларының күңел халәтләрен тирәнтен тоеп җиткерә, тормыш тудырган четерекле хәлләрдә аларның холкын төрле яклап ача, шул рәвешчә сәнгатьле һәм тирән эчтәлекле образлар иҗат итә. Ш. комик рольләрне дә җиңел башкара, сәхнәдә үзен иркен тота, Гөлбикә («Яшел эшләпә», Г.Насрый), Нурсәнә («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит) образларын водевильчә шуклык б-н оста гәүдәләндерә. Ш. башкарган Зөбәрҗәт («Уеннан уймак», З.Шаһиморат), Галиябану (шул исем. әсәр буенча, М.Фәйзи), Тереза («Терезаның туган көне», Г.Д.Мдивани), Стёха («Назар Стодоля», Т.Г.Шевченко), Сәлимә («Умырзая», В.Сәйфуллин), Таңчулпан («Карагол», Д.Юлтый) рольләре актрисаның күпкырлы талантын ачарга булышлык итә.

*Әд.:* И л я л о в а И. Театр имени К.Тинчурина. К., 2002. *И.И.Илялова.*

**ШАҺИ́ЕВ** Марат Муллахмәт улы (29.5.1951, Яшел Үзән ш.), цирк артисты, ТРның халык артисты (1995). Мәскәүдә Бөтенсоюз үзәк цирк сәнгате студиясен («акробат-жонглёр» белгечлеге) тәмамлый (1970). 1970–92 елларда «Союзгосцирк» системасында, В.Деев җитәкчелегендә «Җилкә акробатлары» («Плечевые акробаты»), Д.Х.Гыйбадуллин җитәкчелегендә «Акробат-жонглёрлар» номерларында чыгыш ясый. 1992 дән Зур Мәскәү циркында. Халыкара һәм Бөтенроссия цирк сәнгате фестивальләрендә катнаша, 1 нче Бөтенсоюз цирк артистлары конкурсы (Мәскәү, 1982), Халыкара цирк артистлары конкурсы (Голландия, 1998) лауреаты. «5,6 тәлинкәне бер атуда тарату» трюгын бердәнбер башкаручы.

**ШАҺИ́ЕВ** Эдуард Мөстәкыйм улы (17.3.1944, Омск ш.), график, нәкышьче, БАССРның атказ. рәссамы (1989). Свердловск сынлы сәнгать уч-щесен (1965), Мәскәү югары сәнгать-сәнәгать уч-щесен (элекке Строганов уч-щесе) (1971) тәмамлый. Рәссамнар берлеге (1976), Мәскәү «Рәссам» татар-башкорт рәссамнар берлеге әгъзасы (1999 елдан — рәисе). Ш.нең башлангыч иҗаты станлы графика сәнгате (офорт, автолитография, линогравюра) һәм китаплар бизәү б-н бәйле. «Детская литература», «Современник», «Советский писатель» нәшриятлары б-н хезмәттәшлек итә. В.Маяковскийның «Нәрсә ул яхшы?» («Что такое хорошо?», 1967), А.Гыйрфановның «Дан туртасы» («Пузыри Славы», 1975), Ф.Исәнгуловның «Урман читендәге имәннәр» («Дубы на опушке», 1976), М.Ауэзовның «Ерткыч» («Лютый») (1977), У.Шекспирның «Гамлет» (1978), Г.Рамазановның «Төсләр балкышы» («Многоцветье», 1980), А.Хәсәновның «Тугрылык» («Верность») (1984) һ.б. китапларны бизәүче һәм илл. авторы. Басма графика сәнгате үсешенә зур өлеш кертә. «Мәрмәр төркем» (1978), «Каршылыклар аша», «Кызыл Армия төзелү» (икесе дә — 1978–87), «Төньяк амурлары» (1979), «Җиңү истәлегенә» (1984) серияләре; «Саумы, кадерле Ватан!» (1986), «Оркестр репетициясе» (1987), «Парадка әзерлек» (1987–88), «Безнең тарих — картиналарда» (2003–05), «Җиңүче сугышчыларга дан» (2004) график эшләре авторы.

1980 еллар уртасыннан станлы сәнгать өлкәсендә эшли. Ил сәнгате сюрреализмының әйдәп баручыларыннан берсе. Россиядә үзгәртеп кору һәм аннан соңгы чынбарлыкны фәлсәфи һәм кайвакыт сарказм катыш ирония б-н чагылдыра. Ш.ның иҗат гәүдәләнешенә четрекле, хәтта абсурд дәрәҗәсендәге, фантазия, символлар һәм аллегория куллану, эротизм һәм әхлакый-социаль кыйммәтләрне парадоксаль кабул итү хас. Әсәрләре тематик серияләргә берләштерелгән (темпера, майлы буяу, киндер, оргалит): «Ростраль монументлар» (1987), «Бер башлы бөркет», «Яшәү яхшырды...» (икесе дә — 1988), «Йөгерүче мишень» (1991), «Ирониядә сюр гыйбрәтләре» (1980–92), «Эротик сюр гыйбрәтләре» (1986–92), «Йөзләр» (1987–90), «Диван сериясе» (1991–03), «Ерак бабаларның аллегорик портретлары» (1995) һ.б. «Балалар бакчасында чыршы бәйрәме күңелле булачак», «Төп казанышларның киләчәктәге саклаучылары» (икесе дә — 1991) инсталляцияләрен куя. Милли тематикага да мөрәҗәгать итә: «Суда Сабан туе» (1988), «Сабан туе» (1991; 2004) серияләре, «Башкорт биюе «Өч туган» (1991) картинасы.

2000 еллардан Ш. иҗатында төп урынны спорт тематикасы ала, ул җиңел ирония б-н Россия элитасы вәкилләренең мавыгуларын чагылдыра: «Аристократлар рулеткасы», «Аучылык һәм балыкчылык» (икесе дә — 2000–02), «Бильярд аристократиясе» (2000–03), «Костюмлы гольф» (2001), «Казино, рулетка, карта» (2003), «Тарихи шәхесләр бильярд өстәле артында» (2003–04), «Россия гольфы персоналары» (2009) һ.б. графика серияләре (катнаш техника, акварель, гуашь, каләм); «Мәңгелек гольф», «Мәңгелек бильярд» (икесе дә — 2007–08), «Декабрьдә соңгы балык тоту», «Күчмә фотопленәр» (икесе дә — 2009) һ.б. нәкышь цикллары.

1 нче Бөтенроссия китап күргәзмә-конкурсында (Мәскәү, 1976; Б. Ручьёвның «Любава» (1975) китабы бизәлеше өчен диплом), «Мәскәү–Казан» (Мәскәү, 2000), «Казанның 1000 еллыгына» (Дубна ш., 2005), «Рәссам» берлеге» (Мәскәү, 2001, 2011) күргәзмәләрендә, 5 нче Халыкара гольф-индустрия күргәзмәсендә (Мәскәү, 2008), «Ретро-стиль» 7 нче Мәскәү фестивалендә (2008) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Мәскәүдә (1992, 1999–2003, 2005–06, 2008–17), Казанда (1995, 2010), Уфада (2017) уза. Әсәрләре Шәрекъ халыклары сәнгате музеенда, Кораллы Көчләр Үзәк музеенда, Мәскәүдә «Бородино сугышы» музей-панорамасында, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, шәхси тупланмаларда саклана. Медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Эдуард Шагеев. Живопись. Графика: Каталог. М., 1992; И в а н ы ч е в а О. Мифические романы Эдуарда Шагеева // Женщина. 1995. № 23. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ШАҺИ́ЕВА** Розалина Гомәр кызы (28.7.1945, Яшел Үзән р-ны Бишнә а.), шагыйрә, тәрҗемәче, сәнгать белгече, музей хезмәткәре, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2017). Татар һәм рус телләрендә иҗат итә. Казан ун-тын тәмамлый (1968). ТР Дәүләт сынлы







Э.М.Ш а һ и е в. 1. «Исәнме, кадерле Туган илем». Линогравюра. 1986; 2. «Тормыш яхшырды...». Оргалит, темпера. 1988; 3. Татар биюе «Әпипә». «Сабан туе» графика сериясе. 1991.

сәнгать музеенда фәнни хезмәткәр (1969 елдан), Татарстан сәнгате бүлеге мөдире (1990–91) булып эшли. 1991 дән «Казан» милли мәдәният үзәгендә сәнгать бүлеге мөдире, директор урынбасары (1994–2008), бер үк вакытта, 2008–10 да, «Хәзинә» галереясы мөдире. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1991).

Татар сәнгате коллекциясе (1920 елларга караган шәмаилләр, графика) туплый. Музей экспозицияләре авторы, Милли мәдәният музее, Б.Урманче музее концепцияләре автордашы. Хезмәтләре (альбомнар, күргәзмә каталоглары, мәкаләләр) татар халкының гамәли-бизәлеш сәнгатенә, Татарстан рәссамнарының иҗатына (Б.Урманче, Ф.Таһиров, Т.Хаҗиәхмәтов, И.Зарипов, В.Попов, В.Скобеев, Ш.Нигъмәтуллин, Ә.Ильясова, Р.Кәримуллин, Р.Килдебәков һ.б.), татар китабы сәнгатенә һ.б. багышлана. Казанда Солтангалиев мәйданында куелган «Ефәк юлы», «Казанның барлыкка килүе», «Чыңгызхан турында риваять» театральләштерелгән тамаша-мистерия куелышларының сценарийларын яза (1995). «Кара мәрҗәннәр» (1997), «Ниса» (2003), «Шигърият — тереклек суы» (2011) һ.б. шигырь җыентыклары авторы. Ш.ның шигъриятенә метафоралылык, мифологизм хас. Шигырьләре хискә бай, драматик рухлы. Аларда еш кына борынгы төрки поэтик жанрлар хәзерге шигырь формалары б-н үрелеп бара. К.Насыйри, Дәрдемәнд, Ф.Хөсни, С.Хәким, Р.Фәйзуллин һ.б. әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә. Дәүләт бүләге Татарстанның милли мәдәни мирасын өйрәнүгә багышланган «Мәңгелек гөлчәчәкләре: татар һәм рус телендәге мәкаләләр җыелмасы» (2015) китабы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ф ә й з у л л и н Р. Розалина — гөлсукмак... // Казан утлары. 1998. № 4; Л а г у т и н а О. На роду написано быть поэтом // Казань. 2009. № 3. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ШАҺИМӘРДА́НОВ** Равил Габделнур улы (21.3.1936, Казан), эколог, техник фән. канд. (1969), РФнең атказ. экологы (2003). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), а.х.н механикалаштыру уч-щесендә (Биектау р-ны Усад а.) эшли. 1961–63, 1967–76 елларда Казан а.х. ин-тында. 1976–91 дә Урал су хуҗалыгы фәнни-тикшеренү ин-тында (Свердловск ш.) гидрология һәм су ресурслары бүлеге мөдире. 1991 дән Казанда: Россия су хуҗалыгы фәнни-тикшеренү ин-тының Югары Идел ф-лы директоры (1993 кә кадәр). ТР ФА Табигать системалары экологиясе ин-тын оештыручыларның берсе һәм директоры (1993–2009). Бу елларда ин-тның яңа корпусы төзелә. Хезмәтләре гидрологиягә, мелиорацияләнгән җирләрне рациональ куллануны модельләштерүнең теоретик һәм гамәли нигезләренә карый. Ш. җитәкчелегендә кече елгаларны гидрологик-геогр. өйрәнү алымнары эшләнә, елга агымының формалашуында антропоген тәэсирләрнең күләме билгеләнә, ТР терр-ясенең гадәттән тыш экологик хәлләр барлыкка килүгә бирешүчәнлеген фәзаи анализлау һәм картографияләү буенча комплексы методологик тикшеренүләр үткәрелә. Ш. катнашында «Татарстан Республикасының экологик ситуацияләр картасы» (1994), «Татарстан Республикасы. Тискәре экологик ситуацияләр» (2002), «Татарстан Республикасының аеруча саклаулы табигать территорияләре дәүләт реестры» (1998, 2007) һ.б. басылып чыга. Медальләр б-н бүләкләнә. Казан аграр ун-тының шәрәфле профессоры (2005).

Х е з м.: Длины малых рек Республики Татарстан: Справ. К., 2003 (автордаш); Водные объекты Республики Татарстан: Справ. К., 2006 (автордаш).

**ШАҺИМОРА́Т** Зәйни Әхмәт улы (7.3.1913, Оренбург өлкәсенең Тоцкий р-ны Кондызлытамак а. — 25.8.1980, Казан), драматург. Ташкент укытучылар ин-тын (1930), Татар сәнгать техникумын (1936) тәмамлый. 1935 елдан Казанда. 1941–53 тә Халык иҗаты йортында эшли, директор (1946 дан). Казан һәм Башкорт курчак театрларында куелган «Шүрәле» (1938), «Мәч-Мәчин» (1939), «Айтуган» (1941), «Кечкенә партизаннар» (1947), «Бәхет кошы» (1956) һ.б. драма балладалары авторы. «Әнҗе бөртекләре» (1948), «Тугыз гашыйк» (1957), «Таң җыры» (1960), «Әй, әшнәләр, әшнәләр!» (1968) һ.б. пьесалары рев-ция каһарманнарына, алдынгы хезмәтчәннәргә багышлана. Аларның күбесе Татар дәүләт күчмә театры һәм Минзәлә татар драма театры тарафыннан куела. Т.Г.Шевченко, А.Н.Островский һ.б. авторлар пьесаларын татар теленә тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: пьесалар. К., 1973; Гөмбәз асты серләре. К., 1979.

*Әд.:* И ш м о р а т Р. Зәйни Шаһиморатовның тууына 70 ел // Казан утлары. 1983. № 3.

**ШАҺИМОРА́ТОВ** Мәрдегалләм Галиәсгар улы (5.9.1928, Спас кантоны Коры Көрнәле а.), вальцовкалаучы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1976). 1955–88 елларда «Казанрезинотехника» ҖБдә эшли: ябыштыручы, слесарь-ремонтлаучы, вальцовкалаучы. Дәүләт бүләге хезмәттәге югары казанышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШАҺИМОРА́ТОВА** Альбина Әнвәр кызы (17.10.1979, Ташкент), җырчы (колоратуралы сопрано), ТРның халык (2009), РФнең атказ. (2017) артисты. 1998 елдан Казан консерваториясенең дирижёрлык-хор, бер үк вакытта, 1999 да, вокал ф-тларында укый. 2004 тә Мәскәү консерваториясен (Г.Писаренко классы) тәмамлый, 2006–08 дә «Хьюстон Гранд-опера»да (АКШ) стажировка уза. 2004–06 да — К.С.Станиславский һәм Вл.И.Немирович-Данченко исем. Мәскәү муз. театры, 2007 дән Татар опера һәм балет театры солисты. Россия һәм чит илләр буйлап гастрольләрдә йөри, Зур театр, «Ла Скала» (Италия), «Метрополитен-опера», «Хьюстон Гранд-опера», Сан-Франциско, Лос-Анджелес (АКШ) шәһәрләрендәге опера театрлары, Вена, Гамбург опералары һ.б. сәхнәләрендә танылган опера партияләрен башкара. Халыкара муз. фестивальләрдә, ш.и. Зальцбургта (Австрия) Моцарт исем., «Флорентийский май» (Италия) фестивальләрендә катнаша. Р.Муть, З.Мет, Вл. Спиваков, Вл. Федосеев, Ф.Мансуров, А.Фомани, А.Фишер, С.Сондецкис, Р.Салаватов, П.Симмерс, А.Сладковский, Б.Тевлин җитәкчелегендәге симф. оркестрлар б-н чыгыш ясый. Репертуарын Графиня, Донна Анна, Төн патшабикәсе («Фигароның өйләнүе», «Дон Жуан», «Тылсымлы флейта», В.А.Моцарт), Джильда, Виолетта («Риголетто», «Травиата», Дж.Верди), Лючия («Лючия ди Ламмермур», Г.Доницетти), Микаэла («Кармен», Ж.Бизе), Аккош-патшабикә, Шамахан патшабикәсе («Салтан патша турында әкият», «Алтын әтәч», Н.Римский-Корсаков), Зәйтүнә («Шагыйрь мәхәббәте», Р.Ахиярова) опера партияләре; «Реквием» (В.А.Моцарт), «Реквием» (Дж. Верди), «Stabat Mater» (Дж.Перголези), «Немец реквиемы» (И.Брамс), 8 нче симфония (Г.Малер), «Глория» (Ф.Пуленк) соло партияләре, Р.Глиэр оркестры б-н сопрано өчен концерт һ.б.; Көнбатыш Европа, рус, татар композиторларының (С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов, Р.Яхин, А.Монасыйпов һ.б.) камера-вокаль әсәрләре, татар халык җырлары («Әллүки», «Гөлҗамал», «Бөдрә тал») һ.б. тәшкил итә. Җырчының тавышы аеруча аһәңле һәм җиңел яңгырашлы булуы, башкаруы югары профессиональлеге, артистларча образга керү осталыгы б-н аерылып тора. Халыкара һәм бөтенроссия конкурслары: Бөтенроссия опера җырчылары ачык конкурсы (С.-Петербург, 2002), Ф.Виньяс исем. Халыкара опера җырчылары конкурсы (Барселона, 2003), М.Глинка исем. 21 нче халыкара конкурс (Чиләбе, 2005, 1 нче



А.Ә.Шаһиморатова.





А.Ә. Ш а һ и м о р а т о в а: 1. Людмила («Руслан һәм Людмила» операсы, М.Н.Глинка); 2. Төн патшабикәсе («Тылсымлы флейта» операсы, В.А.Моцарт) рольләрендә.

бүләк), П.Чайковский исем. 13 нче халыкара конкурс (Мәскәү, 2007, 1 нче бүләк һәм алтын медаль) һ.б. конкурслар лауреаты. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (2011), РФ Театр эшлеклеләре берлегенең «Алтын битлек» (Золотая маска») милли бүләге (2012) лауреаты.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ШАҺИСОЛТА́НОВА** Гадилә Әхәт кызы (10.2.1929, БАССРның Баймак р-ны Юлык а. – 29.12.2011, С.-Петербург), химик, химия фән. д-ры (1971), проф. (1973), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991). Ленинград технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), СССР ФАнең Радий ин-тында (Ленинград) эшли, 1961 елдан Белорус ун-тының (Минск) сирәк һәм авыр металлар фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире, 1971 дән Лениград технол. ун-тында. 1977 дән Россия пед. ун-тының (С.-Петербург) нәорганик химия каф. мөдире, 1993 тән профессор. Илдә координацион кушылмалар фотохимиясе мәктәбенә нигез салучы. Хезмәтләре күчешле металлар координацион кушылмаларының электрон-ярсулы халәте теориясен булдыруга һәм үстерүгә багышлана. Ш. металл комплексларын файдаланып, диэлектриклар металлау теориясен, күчешле металларның координацион кушылмалары эремәсендәге беренчел фотохимик процесслар концепциясен, басма платаларны һәм фотографик материалларны ясауның фотоаддитив технологиясен, мәгълүматны фотохимик ысуллар б-н язып алуны тәкъдим итә. Илдә беренче координацион кушылмалар фотохимиясе лаб-ясен оештыра. Ш. супрамолекуляр фотохимияне эшләүдә катнаша, бу юнәлеш күчешле металларның комплекслы кушылмалары нигезендә яңа буын наноүлчәмле материалларны булдыруны максат итеп ала. Уйлап табуга 18 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар. СССР югары белем бирү отличнигы (1987), СССР халык мәгарифе отличнигы (1989). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фотохимические и радиационно-химические процессы в водных растворах и твёрдых телах. Минск, 1970; Возможности метода РФЭ спектроскопии при изучении строения и свойств полимеров на основе комплексных соединений переходных металлов с основаниями Шиффа // Журн. неорг. хим. 2005. Т. 50. № 6.

**ШАҺМА́ЕВ** Марат Мөхәммәт улы (14.8.1932, Новосибирск өлкәсенең Кыштовка р-ны Уразай а. — 22.9.2001, Казан), радиотехник, физика-матем. фән. д-ры (1994), проф. (1997). Томск политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Новосибирск шәһәре пр-тиеләрендә эшли. 1969 елдан Казан техник ун-тында, радиоэлектрон һәм квант җайланмалары каф. профессоры (1995 тән). Хезмәтләре радиоэлемтәдә бер буйлы модуляциягә карый. Почмак модуляциясе нигезендә киң буйлы булүчеләр, икегә тапкырлаучылар һәм күп кабатлы тапкырлаучылар эшенең принципларын тәкъдим итә һәм схемаларын эшли.

Х е з м.: Теория и методы расчёта дифференциальных схем частотных и фазовых модуляторов. К., 1979; Однополосная угловая модуляция в радиосвязи. К., 1991; Приёмники сигналов с однополосной частотной модуляцией. К., 1998.

**ШАҺМОРЗА́ЕВА** Зариус (Зоря) Госман кызы (26.10.1933, Казан — 24.4.2010, Мәскәү), скрипкачы, педагог, ТАССРның атказ. артисты (1972). 1957 елда Мәскәү консерваториясен (А.Ямпольский классы) тәмамлый. 1959–74 тә — музыка уч-щесендә, 1963–79 да — Мәскәү консерваториясендә укыта, бер үк вакытта, 1966 дан, Мәскәү филармониясе солисты. Татар композиторларының (М.Мозаффаров, З.Хәбибуллин һ.б.) скрипка өчен язылган күп кенә әсәрләрен беренче булып башкаручы. Илебездә һәм чит илләрдә гастрольләрдә йөри. Укучылары арасында халыкара конкурслар лауреатлары, концертлар б-н чыгыш ясаучылар, педагоглар Е.Бушков, М.Катаржнова, Н.Должников бар. 6 нчы Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале сәнгать конкурсы (Мәскәү, 1957), П.И.Чайковский исем. (Мәскәү, 1958), М.Лонг-Ж.Тибо исем. (Париж, 1961), Бельгия королевасы Елизавета исем. (Брюссель, 1963) халыкара конкурслар лауреаты.

*Ф.Ш.Салитова.*

**«ШАҺСӘНӘ́М ҺӘМ ГАРИ́Б»**, гомумтөрки китап *дастаны*. Ихтимал, теленең катлаулылыгы аркасында беркайчан телдән сөйләнмәгән, кулъязма һәм басма чыганакларда гына очраган. 18 йөз ахырыннан төрки (төрекләрдә, төрекмәннәрдә, әзәрбайҗаннарда, үзбәкләрдә) һәм хәтта төрки булмаган (әрмән, кабардин, грузин) халыкларда киң таныла. Татарларга 19 йөз ахырыннан мәгълүм була. Әсәрдә хан (падишаһ) кызы б-н вәзир улының Шәрекъ әдәбияты өчен традицион булган трагик мәхәббәт темасы үстерелә. Балалар туганчы ук, аларның аталары кыз б-н малай тугач туганлашу турында килешәләр. Ак вәзир һәлак булганнан соң, Габбас хан карарын үзгәртә. Балалар бер мәктәптә укыйлар һәм бер-берсенә гашыйк булалар. Ачуы кабарган хан кызына Гариб б-н очрашырга рөхсәт итми, әмма гашыйклар элеккечә үк яшерен рәвештә очрашалар, аларның мәхәббәте көчәйгәннән-көчәя бара. Гариб, Шаһсәнәмне аңа кияүгә бирмәячәкләрен аңлап, өметсезлектән коега ташлана. Шаһсәнәм дә сөйгәне артыннан коега сикерә. Соңрак геройларның үлеме татар героик эпосының традицион мотивына әверелә. Беренче булып «Ш.һ.Г.» нең татар версиясен әлеге дастанны өйрәнүче, фольклорчы Ф.В.Әхмәтова нәшер итә.

*Әд.:* Ә х м ә т о в а Ф. Татар халык дастаннары // Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; У р м а н ч е е в Ф. Героический эпос татарского народа. К., 1984.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ША́ЦКИХ** Павел Александрович (28.7.1974, Киров ш.), хакимият-хуҗалык хезмәткәре, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1998). 1994–2002 елларда Казан сәнәгать пр-тиеләрендә һәм учреждениеләрендә эшли. 2006 дан «Казан «Электроприбор» заводы» АҖдә: ген. директор урынбасары, ген. директор (2007 дән). Дәүләт бүләге материаллар һәм эшләнмәләрнең өслеген эшкәртү процессында кулланыла торган электролитик электродлар б-н (күп каналлы бушану) электр бушануларының яңа төре нигезләрен



З.Г.Шаһморзаева.



В.Д.Шашин.

эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ША́ШИН** Валентин Дмитриевич (16.6.1916, Баку — 22.3.1977, Мәскәү), нефтьче, дәүләт эшлеклесе, СССРның Ленин бүләге лауреаты (1962). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1943), Башкортстанның нефть промыслаларында эшли. 1953 елдан «Татнефть» ҖБдә, башлык (1955 тән), бер үк вакытта, 1958 дән, Татарстан ХХСның Нефть сәнәгате идарәсендә. 1963 тән РСФСР ХХСның Нефть һәм газ сәнәгате баш идарәсе башлыгы , 1965 тән СССР нефть сәнәгате министры. Татарстан һәм СССРның башка төбәкләре терр-яләрендә эре углеводород чыганакларын ачу һәм эшкәртүне оештыручы. Ш. ТАССРда чыганакларны эшкәртү буенча яңа технологияләр кертә, бу исә нефть чыгару күләмен шактый арттыру мөмкинлеге бирә: 1950–60 елларда Татарстан СССРда нефть чыгаручы төп төбәккә әверелә. 1956 да нефть чыгару күләме буенча респ-ка СССРда 1 нче урынга чыга. Ленин бүләге нефть чыгару өлкәсен яңа фәнни-техник казанышлар нигезендә үзгәртеп җиһазлауны оештыруы өчен бирелә. 1953–63 тә ТАССР, 1965–77 дә СССР ЮС депутаты. 4 Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. «Татнефть» АҖнә, Бөгелмә һәм Лениногорск (һәйкәл урнаштырылган) шәһәрләре урамнарына, ике диңгез судносына Ш. исеме бирелгән.

*Әд.:* В а х и т о в Г.Г. В.Д.Шашин и развитие науки. М., 1996.

**ШАШЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Ашыт елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 14,8 *км*. Бассейнының мәйданы 65,7 *км*[2]. Вятка увалы калкулыгыннан, Әтнә р-нында ага. Елга башы Чембулат авылыннан 0,6 *км* төньяктарак, тамагы Түбән Шашы авылыннан 1 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 101 *м*. Су җыелу мәйданында урман үсемлекләре бөтенләй юк. Елганың 0,2 дән 5,2 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км*2. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*[2]. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче унконлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,035 *м*[3]*/с*. Җәен озак вакыт яңгырлар булмаганда елганың

һәм аның кушылдыкларының аерым урыннары кибә. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Ш. бассейнында суының гомуми күләме 1,8 млн. $м^3$ булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШӘБЕ́З** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Агыйдел елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 35 *км*. Бассейнының мәйданы 335,5 $км^2$. Актаныш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Апач авылыннан көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Агыйдел елгасының сазлыклы сулъяк тугаенда, Бурсык авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 155 *м*, тамагыныкы — 63 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Ш.нең 0,4 тән 5 *км* га кадәр озынлыктагы 10 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,15 *км/км²*. Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык чыгымы 67 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 50 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,2 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Ш. бассейнында суының гомуми күләме 2,1 млн. $м^3$ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШӘБЕ́З** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 22 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 147 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. 1723 тән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.дә мәчет (1830 дан билгеле), мәктәп, җил тегермәне, ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1814,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров (Өшәр) волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 187, 1816 да — 131, 1834 тә — 165 ир-ат; 1859 да — 394, 1870 тә — 411, 1884 тә — 547, 1897 һәм 1906 да — 549 ар, 1913 тә — 463, 1920 дә — 409, 1926 да — 354, 1938 дә — 405, 1949 да — 286, 1958 дә — 276, 1970 тә — 267, 1979 да — 244, 1989 да — 191, 2002 дә — 165 кеше.

**ШӘБЕЗБА́Ш** посёлогы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 31 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 67 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәчет. 1747 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1773–75 тәге Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Ш.та мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 557 дис тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 66, 1859 да — 218, 1870 тә — 229, 1884 тә — 269, 1897 дә — 307, 1906 да — 395, 1913 тә — 379, 1920 дә — 287, 1926 да — 315, 1938 дә — 273, 1949 да — 186, 1958 дә — 152, 1970 тә — 182, 1979 да — 111, 1989 да — 78, 2002 дә — 65 кеше.

**ШӘВӘЛИ́ЕВ** Рафаэль Фирнаял улы (12.5.1974, Актаныш р-ны Пучы а.), хирург, мед. фән. канд. (2015), ТРның атказ. табибе (2014), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2015). Казан мед. ин-тын (1997), Казан (Идел буе) федераль ун-тын (2011), РФ Президенты каршындагы «Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе»н (2014) тәмамлый. 1997–98 дә Казан мед. академиясендә табиб-интерн, 1998–2000 дә Менделеев Үзәк район хастаханәсендә табиб-хирург, 2000–07 дә Казан онкология диспансерында табиб-онколог, 2007–09 да РТ Сәламәтлек саклау министрлыгында эшләр башкару идарәсе башлыгы, 2009–10 да Казан шәһәре Сугыш ветераннары госпитале җитәкчесе, 2010–18 дә Респ-ка балалар клиник хастаханәсе баш табибе, 2018 дән Респ-ка клиник хастаханәсе баш табибе. Дәүләт бүләге Татарстанда йөрәк һәм кан тамыры авырулары булган балаларга хирургия ярдәме күрсәтүгә карый.

Х е з м.: Современные аспекты оказания экстренной и реанимационной помощи детям // Российский педиатрический журнал. 2014. № 3 (автордаш); Офис участкового педиатра – новая форма организации медицинской помощи в условиях детской городской поликлиники // Российский педиатрический журнал. 2015. Т.18. № 6 (автордаш); Профилактика редких болезней: современные аспекты и новые вызовы // Российский педиатрический журнал. 2017. Т.20. № 4 (автордаш).

**ШӘДКЕ́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 22 *км* көньяктарак, Нырсы елгасы буенда. 2010 елда 785 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шәдче исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1850 елларда поташ з-ды, 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1673 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Казиле волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 40 ир-ат; 1859 да — 503, 1897 дә — 941, 1908 дә — 1040, 1920 дә — 1148, 1926 да — 976, 1938 дә — 987, 1949 да — 939, 1958 дә — 882, 1970 тә — 998, 1979 да — 937, 1989 да — 798, 2002 дә — 806 кеше.

**ШӘДЧЕ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 27 *км* төньяктарак, Шыя елгасы (Вятканың уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 488 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Икмәк з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөз ахырында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кулрыс төшерү-мунчала ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.дә 2 мәчет, мәдрәсә, 3 ярма яргыч, йон-тукыма ману йорты, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1162,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 64 ир-ат; 1859 да — 623, 1897 дә — 1086, 1908 дә — 1220, 1920 дә — 1152, 1926 да — 1021, 1949 да — 772, 1958 дә — 653, 1970 тә — 694, 1979 да — 650, 1989 да — 517, 2002 дә — 494 кеше.

**ШӘЕ́Х** (гарәп. شيخ — өлкән кеше, аксакал, юлбашчы), Гарәбстанда әмирлек идарәчеләренең һәм күчмә кабилә җитәкчеләренең, соңрак — танылган мөселман дин эшлеклеләренең, дини гыйлем белгечләре һәм мөгаллимнәренең, суфилык борәдәрлеге башлыкларының, үзләренең тәкъвалыклары б-н билгеле кешеләрнең мактаулы титулы.«Ш.» сүзе мөселман руханилары титуллары һәм ш.у. татар ялгызлык исемнәре эчендә дә була (Шәйхелислам, Габделшәех һ.б.). Ш.у.к.: *Шәйхелислам.*

*Әд.:* Ислам: Энцикл. Словарь. М., 1991.

**ШӘЕ́Х ӘҮЛИЯ́Р ХАН** (?–1516), Касыйм ханы (1512 елдан соң). *Әхмәд ханның* бертуганы Бәхтияр Солтан улы. *Шаһгали, Җангали* ханнарның атасы. 1502 дә Кырым ханы Миңлегәрәй Олы Урданы тар-мар иткәннән соң, Хаҗитархан шәһәреннән качып, бөек Мәскәү кенәзе Иван III гә хезмәткә керә. Аның карамагына Сурожик шәһәрчеге (Звенигород ш. янында) бирелә. 1508 дә рус гаскәренең Литва җирләренә явында катнаша, 1512 дә татар гаскәри берләшмәсенең яубашы булып Смоленск шәһәренә яу б-н бара. Мәскәү бөек кенәзе Василий III хөкемдарлыгы дәверендә Җанай хан үлеменнән соң (1512) Касыйм ханлыгы тәхетенә утыртыла.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863. Ч. 1.

*И.Л.Измайлов.*

**ШӘЕ́Х ӘХМӘ́Д ХАН** (?-1528), Олы Урда ханы (1481 дән). *Әхмәд хан* улы. Атасы үлгәннән соң хакимият башына килә. 1490 елларда Кырым ханы Миңлегәрәйгә, Себер ханы Ибакъка каршы тора. Бөек Литва кенәзлеге б-н мөнәсәбәттә була. Кырым ханлыгына каршы көрәштә җиңелә. 1502 дә Миңлегәрәй

хан гаскәре Олы Урданы тар-мар итә. Ш.Ә.х. Хаҗитарханга, соңыннан Нугай Урдасына кача. 1504 тә Киевта булган чагында кулга алынып, Литва бөек кенәзе Александрга тапшырыла; озак вакыт әсирлектә була. Азат ителгәннән соң (1527), Әстерхан ханлыгында яши.

*Әд.:* П о ч е к а е в Р.Ю. Цари ордынские: Биографии ханов и правителей Золотой Орды. СПб., 2010.

**ШӘЕ́Х** (Шәехов) Ленар Миңнемөһим улы (4.10.1982, Актаныш р-ны Такталачык а.), шагыйрь, тәрҗемәче, журналист, филол. фән. канд. (2012). ТР Журналистлар берлеге (2006), Халыкара Журналистлар ассоциациясе – IFJ (2006), Халыкара ПЕН-клубның Татар ПЕН-үзәге (2007) әгъзасы. Казан ун-тын тәмамлый (2007). 2004 елдан «Азатлык» радиостанциясенең Казан бюросында, бер үк вакытта «Шәһри Казан» (2004–05), «Татарстан яшьләре» (2005–07) г-талары хәбәрчесе. 2007 дән Татарстан китап нәшриятында, 2009 дан баш мөхәррир. Балалар өчен «Авылдан килгән мендәр» (2005), «Керпе ничек энәле булган» (2007), «Алдамыйм!» (2014), «Безнең урманда» (2017) һ.б. шигъри җыентыклары дөнья күрә. Ш. – ш.у. лирик, фәлсәфи һәм юмористик-сатирик шигырьләре тупланган «Дүртенче кат... Бишенче кат...» (2008), «Җылытасы килә дөньяны!» (2011), «Бар бездә берәү!..» (2015), «Мәхәббәт турында шигырьләр» (2016) һ.б. җыентыклар авторы. Шигырьләре рус, кыргыз, инглиз телләренә тәрҗемә ителә. Т.Шакирова б-н бергә «Балачак энциклопедиясе»н төзи (1–5 китап, 2009–13). ТРның М.Җәлил исем. Респ-ка бүләге (2013), ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. әдәби бүләге (2017), Идел буе «NEWBOOK. Волга – 2015» әдәби бүләге (2015) лауреаты; әдәбият, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә Халыкара Евразия бүләгенең алтын лауреаты (2018); VI Халыкара «Open Eurasian Literature Festival @ Book Forum» әдәби фестиваленең «Кече проза» номинациясендә Гран-при иясе (Швеция, Стокгольм ш., 2017).

Ә с ә р.: Гасырда фасыллар буталган: шигырьләр = Заблудились мгновенья в веках: стихотворения. К., 2016; Балбан бала = Амбал малай: балалар өчен шигырьләр. К., 2016; One of you: the collection of poems. L., 2017.

Х е з м.: Татар шигъри трагедиясе: монография. К., 2016; Үзем белән очрашу: әңгәмәләр, әдәби портретлар, иҗат бәяләмәләре, язмалар, сәяхәтнамәләр, уйланулар, хикәяләр. К., 2018.

*Әд.:* Ю з е е в И. Җанда – бер чәчәк... // Казан утлары. 2004. №4; Ш и һ а п о в М. Уңай эшкә балта чапмыйк // Җырлыйсы җырларым бар әле. К., 2005; М и ң н у л л и н Р. Ленар Шәех // Әсәрләр. К., 2007. Т. 5.; Х ә л и м А. Җылытырга иде // Мәдәни җомга. 2013. 15 март..

**ШӘЕХГАЛИ́** Әскәр Гали улы (15.5.1885, Киев – 29.7.1968, Казан), конструктор; Россиядә гарәп графикалы татар язуы өчен беренче *язу машинасын* ясый (1923). Дворяннар нәселеннән. Г.Д.*Шәехгалинең* улы. Петербург гимназиясен (1905), Петербург ун-тының физика-матем. ф-тын (1912) тәмамлый. 1914 елда рус армиясенә мобилизацияләнә һәм артиллерия уч-щесына укырга җибәрелә (кенәз Ф.Юсупов б-н бергә укый). 1916 дан Беренче бөтендөнья сугышы, 1918 дән — Гражданнар сугышы фронтларында (5 нче армия составында Көнчыгыш фронтта). 1920 дән Кызыл Армия Баш штабының Көнчыгыш бүлегендә (Мәскәү). 1922–24 тә Урман-техник ин-ты (Мәскәү) каршындагы төгәл механика остаханәсе механигы, соңыннан мөдире. Бер үк вакытта Шәрекъ респ-каларындагы, ш.и. ТАССРдагы канцелярияләрдә эш башкаруны механикалаштыру максатында татар телендәге текстларны бастыру өчен гарәп шрифтлы язу машинкасы конструкциясе өстендә эшли. 1924 тә язу машиналарын уйлап табуга ике гариза бирә, алар «зур дәүләти әһәмияткә ия» дип танылa. Татарстан хөкүмәте Ш.нең патентларыннан файдалануга лицензия ала һәм 1924 нең октябрендә татар язуы өчен гарәп шрифтлы нигезендәге язу машиналары җитештерәчәк остаханә оештыру максатыннан аны Казанга чакыра. 1924–29 да ТАССР ҮБК ның машиналар җитештерү остаханәсе, 1930 дан — ТАССР ХХС Татметаллтрестының Казан язу машиналары з-ды («Терминал» ҖБ) техник җитәкчесе. 1924 нең декабрендә пр-тиедә СССР да беренче гарәп шрифты нигезендә ясалган язу машиналарын, 1929 да — латин шрифтлы («Яңалиф») машиналар җитештерү башлана. 1931 нең 6 маенда ОГПУ гаепләве б-н кулга алына, 1932 нең маенда ОГПУ комиссиясе тарафыннан нахакка 5 елга ирегеннән мәхрүм ителеп, Беломорканал төзелешенә җибәрелә. 1934 нең 7 июнендә, гидротехника лаб-ясендә рационализаторлык тәкъдимнәрен гамәлгә кертүе өчен, срогыннан элек азат ителә. 1934–41 дә Мәскәү өлкәсе Истра шәһәрендә Кыллы музыка уен кораллары ф-касында инженер. 1941–45 тә Алатырь шәһәрендә (Чуаш АССР). 1945 тә Казан язу машиналары з-дында инженер-технолог, шул ук елның 22 октябрендә, Казанда теркәлә алмавы сәбәпле, эшеннән чыгарыла. 1945–47 дә Яшел Үзән сәнәгать комб-тының план-икътисад төркеме башлыгы. 1947–59 да Волжск «Марилес» агач эшкәртү комб-тында инженер-конструктор. 1959 да аклана, 1960 та Казанга кайта; төрле техник җайланмалар һәм механизмнарны камилләштерү б-н шөгыльләнә.

Чыг.: к. *Язу машинасы* мәкаләсе.

*Әд.:* Татарча язу машиналары // Безнең юл. 1925. №2; Блестящая победа пишущих машинок «Яналиф»: Массовое производство машин в Казани // Красная Татария. 1930. №12; Даже подпись приравняли к политике // Рос. газета. 2001. 23 окт.; Б а д р у т д и н о в а М., Г а л и м у л л и н а Г. Трагедия изобретателя // Татарский мир – Татар дөньясы. 2010. №4.

*М.Ш.Бәдретдинова, Г.Х.Галимуллина.*

**ШӘЕХГАЛИ́** Гали Дәүләт улы (8.10.1845, С.-Петербург — 1917, шунда ук), генерал-майор, җәмәгать эшлеклесе. Дворяннар нәселеннән. 1860 елда имам Шамил гаиләсе б-н бергә Төньяк Кавказдан С.-Петербургка китерелә. Россия дворян балаларына тәгаенләнгән өстенлекле хәрби уку йорты — 2 нче кадетлар корпусын тәмамлый (С.-Петербург, 1863). 1877–78 дәге Рус-төрек сугышында катнаша. 1860 тан Россия армиясендә хәрби хезмәттә: майор (1874), подполковник (1878), полковник (1883), генерал-майор (1900). 1877 дән — 6 нчы Оренбург казак полкы, 1884 тән — 3 нче Оренбург казак полкы, 1900 дән 1 нче Кавказ казак дивизиясенең 2 нче бригадасы командиры. 1900 нең октябрендә отставкага чыга. 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче дәрәҗә Изге Святослав орденнары б-н бүләкләнә. Татар бәкләре *Тәфкилевләр* нәселеннән килгән Г.С.Тәфкилевага өйләнә. Отставкага чыкканнан соң, иҗтимагый эшчәнлек б-н шөгыльләнә, С.-Петербургның мөселманнар җәмгыятен җитәкли. С.-Петербургта җамигъ мәчет салу эшен башлап йөрүчеләрнең берсе, мәхәллә җыены тарафыннан төзелгән һәм эчке эшләр министры П.А.Столыпин раслаган төзелеш ком-ты составында була (1906). 1891 дә Ш. хатыны б-н бергә аның нәселдән килгән утарында — Вятка губернасындагы Шаршады авылында (хәзер Әгерҗе р-нына керә) мәчет төзетә.

*Әд.:* Отчёт Мусульманского благотворительного общества Санкт-Петербурга. СПб., 1909; И б р а г и м о в Г. Татары в революции 1905 года. К., 1926; А м и н о в Д. Ислам в Санкт-Петербурге. СПб., 1993; ш у л у к. Татары в Санкт-Петербурге: Ист. очерк. СПб., 1994; Н а д ы р о в а Х. Деревянное культурное зодчество Волго-Камья: истоки и традиции. К., 2006.

*М.Ш.Бәдретдинова.*

**ШӘЕ́ХОВ** Марс Фәрит улы (19.7.1968, Казан), химия физигы, технолог, техник фән. д-ры (2007). «Мединструмент» фәнни-җитештерү берләшмәсендә (1988–96), «Ак Барс Банк»та (1996–98) эшли. 1998 елдан Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре түбән басымлы югары ешлыклы бушанышлардагы физик процессларны тикшерүгә, капилляр-күзәнәкле, җепселле һәм онталы материалларны модификацияләүгә, түбән басымлы югары ешлыклы бушанышның нефть продуктларына тәэсирен өйрәнүгә карый. Ш. абразив материаллар өслеген чистарту процессларын эшләүдә, каты эретмәле стоматологик фрезаларның чыдамлыгын арттыруда, түбән темп-ралы плазманы кулланып, югары сыйфатлы сарык тиресе җитештерү, үтә югары молекуляр полиэтиленнан полиэтиленпластик ясау технологиясен эшләүдә катнаша.

Х е з м.: Единый эколого-технологический комплекс модификации среды обитания человека с помощью сорбционной очистки гидросферы. К., 2001 (автордаш); Влияние высокочастотного ёмкостного разряда пониженного давления на свойства текстильных материалов // Прикладная физика. 2004. № 6 (автордаш); Модификация нанослоёв в высокочастотной плазме пониженного давления. К., 2007 (автордаш).

**ШӘҖӘРӘ́** (гарәп. شجره — агач), нәсел агачы, татар, башкорт һ.б. төрки халыкларда генеалогик язма. Язма һәм телдән тапшырылу рәвешендә яшәп килә. Ш.нең төп эчтәлеген нәселнең борынгы бабалардан алып иң соңгы варисларга кадәр вәкилләренең исемлеге тәшкил итә; кайвакыт ул искә алынган затлар тормышыннан мәгълүматлар б-н тулыландырыла. Ш. — үткәннәр турында белемнәрнең иң борынгы формаларыннан берсе. Ул ыруглык җәмгыяте чорында формалаша. Тарихи белемнәрнең башка формалары үсеше барышында икенчел урынны били. Ыруглык мөнәсәбәтләре калдыклары сакланып калган халыкларда, мәс., күчмә халыкларда, Ш. ның саклануын дәвам итә. Аларда «го-













**Шәҗәрә.** 1. Татар шагыйре Г.Тукай шәҗәрәсе. «Авалон медиа группа» ҖЧҖ. Электрон версия. 2011; 2. ТРның беренче Президенты М.Ш.Шәймиев шәҗәрәсе. И.Х.Гайнетдинов, А.Н.Артемьева. Каюлы күн мозаика 2005; 3. Рәссам-хаттат Н.Ф.Исмәгыйлев (Нәҗип Нәкъкаш) шәҗәрәсе. Автор эше. Катнаш алым. 2008; 4. ТР ФА академигы Ә.М.Мазһаров шәҗәрәсе. Р.И.Шәмсутов. Компьютер графикасы. 2013.

мумэтник» («гомуммилли») тарих вазифаларын башкарган гомумыруг, гомумкабилә Ш.ләре өстенлек итә. Утрак тормышлы халыкларда Ш. аерым, ягъни гаилә-фамилия нәсел агачы рәвешендә була; община Ш.ләре төре дә очрый, алар бер яки берничә торак пунктта яшәүче община кешеләре турында генеалогик мәгълүматларны колачлый. Татар Ш.ләренең иң элгәреге үрнәкләре 14–16 йөзләр эпитафияләрендә, 16–18 йөзгә караган тарихи хезмәтләрдә («Җамигъ әт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә» һ.б.) чагылыш таба. Алар аерым ырулар һәм фамилияләрнең социаль чыгышы, татар халкы көченешенең сәбәпләре һәм юнәлешләре, торак пунктлар тарихы буенча мәгълүматларны, татар халкының килеп чыгышы буенча материалларны (тамырлары болгарлардан, Алтын Урдадан, нугайлардан һ.б.дан килүе турындагы мәгълүматларны) үз эченә ала. 1990–2010 елларда татар Ш.ләрен өйрәнүгә М.И.Әхмәтҗанов, А.Б.Беляев зур өлеш кертә. Алар тарафыннан күп кенә атаклы татар нәселләренең, ш.и. Казан, нугай, Касыйм, Әстерхан, Себер татарларының Ш.ләре төзелә. Р.Фәхретдин (М.И.Әхмәтҗанов), М.Бигиев, Г.Гобәйдуллин, С.Сәйдәшев (А.Б.Беляев) кебек күренекле эшлекләренең Ш.ләре торгызыла.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М.И. Татар шәҗәрәләре. К., 2011; У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники XVII – XVIII вв. К., 1972; А х м е т з я н о в М.И. Татарские шеджере. Исследование татарских шеджере в источниковедческом и лингвистическом аспектах по спискам XIX – XX вв. К., 1991; А х м е т з я н о в М.И., Ш а р и ф у л л и н а Ф.Л. Касимовские татары (по генеалогическим и этнографическим материалам). К., 2010; Б е л я е в А.Б. Историческая генеалогия татарского народа. Родственные династии и их роль в истории семьи, нации и государства. К., 2012.

*М.Г.Госманов, Ф.Г.Кәлимуллина.*

**ШӘЙГӘРДА́НОВ** Юрий Әхтәм улы (29.7.1954, БАССРның Уфа р-ны Шакша ст.), кинооператор, РФнең мактаулы кинематографисты (1995). Мәскәүдә Бөтенсоюз кинематография ин-тын тәмамлый (1983, В.Юсов остаханәсе). 1971–73, 1975–78 елларда Казан кинохроника студиясенең Мордва кинохәбәрчелек пунктында оператор ассистенты, «Киң Иделдә» киножурналы өчен 10 га якын сюжет төшерә. Институтта укыган вакытта ук «Мосфильм» киностудиясенең 2 нче операторы булып эшли. «Төлке авы» («Охота на лис», 1979), «Поезд туктады» («Остановился поезд», 1981, икесе дә – реж. В.Ю.Әбдерәшитов) нәфис фильмнарын төшерүдә катнаша. 1983 тән «Ленфильм» киностудиясендә: «Искә төшерик, иптәш» («Вспомним, товарищ», 1987), «Сез кемнәрнеке, картлачлар?» («Вы чьё, старичьё?», 1988), «Сәйяр автобус» («Бродячий автобус», 1989; өчесе дә – реж. И.Хейфиц), «Гамбринус» (1990), «Гамьсезләр» («Циники», 1992; икесе дә – реж. Д.Месхиев) фильмнарының, «Эт йөрәге» («Собачье сердце», 1988, реж. В.Бортко; иң яхшы операторлык эше өчен А.Москвин дипломы һәм бүләге, Италиядә Европа телевизион фильмнары фестивалендә иң яхшы телефильм өчен «Пальма ботагы», 1989) телевизион нәфис фильмының операторы һәм куючысы. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1989).

**ШӘЙДУКО́ВА** Ләйлә Казбек кызы (5.5.1957, Казан), психиатр, нарколог, мед. фән. д-ры (1996), проф. (1998), ТРның атказ. табибе (2015). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), Респ-ка наркология диспансерында эшли. 1984 елдан Казан мед. ун-тының психиатрия кафедрасында, бер үк вакытта, 1986–87 дә, Респ-ка психиатрия хастаханәсендә. Хезмәтләре хатын-кыз алкоголизмының барлыкка килүе, авыруны дәвалау ысулларына, наркоманияне кисәтү һәм авыруларны тернәкләндерү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Женский и супружеский алкоголизм: Актуальные проблемы наркологии. К., 2006; Гендерная наркология. К., 2007; Психодинамические концепции «аддиктивной личности» // Психическое здоровье. 2009. № 10; Социально-гигиенические, клинико-психопатологические, мотивационно-психологические факторы алкоголизма у одиноких и замужних женщин // Рос. психиатр. журн. 2016. № 4 (автордаш).

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**ШӘЙДУ́ЛЛИН** Ильяс Нургали улы (1.1.1948, Куйбышев өлкәсенең Камышлы р-ны Яңа Ярмәк а.), вет. табибе, биол. фән. д-ры (1994), проф. (2001). Ульянов а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Кузовск вет. станциясендә, «Прогресс» с-зында вет. табибе булып эшли (Ульянов өлкәсе). 1975–99 елларда Бөтенроссия терлекчелек фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү өлкәсенең Подольск р-ны Дубровицы штп). 1999 дан Мәскәү вет. медицинасы һәм биотехнол. ин-тында, вак терлекчелек каф. мөдире (2003). Хезмәтләре терлекләрне үрчетү биологиясе һәм ясалма орлыкландыру, хайваннарны климатка яраклаштыру һәм гибридлаштыру, сарыкчылык селекциясе һәм технологиясе, Камчатка өлкәсе шартларында сарыкчылыкны үстерү мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Результаты осеменения овец глубокозамороженным семенем // Овцеводство. 1978. № 9; Гибриды плодовиты // Овцеводство. 1992. № 3–4; Рынок баранины и пути насыщения его отечественной продукцией // Зоотехния. 2009. № 7 (автордаш).

*Әд.:* Ильяс Нургалиевич Шайдуллин (к 60-летию со дня рождения // Овцы, козы, шерстяное дело. 2008. № 1.

**ШӘЙДУ́ЛЛИН** Миңнехан Габдулла улы (12.11.1940, Мамадыш р-ны Хәсәнша а.), монументалист, нәкышьче, график, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1999). Казан сынлы



М.Г.Ш ә й д у л л и н. «Кордон». 2005.

сәнгать уч-щесен тәмамлый (1965). 1965–67 елларда Казанда Сәнгать фондында эшли. 1967 дән Чаллы шәһәрендә: «Камгэсэнергострой»ның баш рәссамы, 1972 дән сәнгать-производство участогы рәссам-монументалисты. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1983). Чаллыда дивар бизәлеше, мозаик панно, скульптуралар, агачка уеп бизәк ясау,



М.Г.Ш ә й д у л л и н. «Әүвәлге транспорт» (автордаш). Җиз, кабырчык токым. Эретеп ябыштыру, чүкү. 1980.

металл композиция (чүкеп бизәк төшерү, эретеп ябыштыру, тапап ясау) авторы. Алар арасында «Энергетик» мәдәният сарае фасадындагы металл детальләр, уеп бизәк төшерелгән агач, гипс рельефлар һәм битлекләр эшләнгән «Тормыш агачы» фризы, «Татарстан» кунакханәсенең банкет залы, «Кама», «Чаллы» рестораннары интерьерлары, Трансагентлык бинасы каршындагы металл «Әүвәлге транспорт» (1980, Г.Иванов, Г.Фёдоров, А.Гәрәев б-н берлектә), 35 нче мәктәп фасадындагы «Быргычылар» скульптура композицияләре, Мәләкәс елгасы аркылы



М.Г.Ш ә й д у л л и н. «Шүрәле авазы». Графика, катнаш техника. 2006.

төзелгән күпернең декоратив кыңгыраулы (җиз) арка рәвешендәге бизәлеше (1970–80) бар. Металлны чүкеп һәм тапап ясалган «Картлар» (1972), «1918 ел» (1974), «Сабан туе», «Көтүче», «20 еллар комсомолы», «Шүрәле» әкияте темаларына (барысы да — 1970 башларында) композицияләр, керамикадан декоратив вазалар авторы.

Станлы сәнгатьтә Ш. күбрәк натура пейзажы жанрында эшли: «Мәңгелек. Болгар» (1990) циклы, «Мәңгелек» (1998), «Сөн елгасы» (1999), «Кордон» (2005), «Ярышлар» (2010) һ.б. картиналар. Графикада иҗатын плакатлар («В.И. Ленин», «Бишьеллыкны — вакытыннан алда!», 1960 еллар), линогравюра («Чулман елгасы турында», 1962) авторы буларак башлый. Станлы графикада (пастель, тушь, катнаш техника) «Иске һәм Яңа Чаллы» (1971–73), «Иске Чаллы» (1998) серияләрен, «Яңа ай тууу» (1980), «Бөркет оясы» (1985), «Иделдә өянкеләр», «Соңгы трамвай», «Чулман өстендә болытлар» (барысы да — 1992), «Шүрәле авазы» (2006) рәсемнәрен иҗат итә. Китап графикасында М.Кашаповның «Кара язмыш» (2001) повестена иллюстрацияләр ясый. Татар әдәбияты һәм сәнгате әһелләреннән «Г.Тукай» (1991), «Р.Фәхретдин» (1998) һ.б. портретлары авторы.

1971 дән төбәкара — «Зур Идел» (1974); бөтенроссия — «Монументалист рәссамнар күргәзмәсе» (Казан, 1977), «16 автономияле республика» (Мәскәү, 1989); халыкара — «Ике автошәһәр» (Париж, 1995), Карловы Вары, Прага (1996) шәһәрләре күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Чаллыда (1998, 1999), Казанда (1998), Әлмәттә (1999) уза. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Р.Фәхретдинов музеенда. Чаллы, Әлмәт картиналар галереяларында, шәхси тупланмаларда саклана. Ш. иҗаты турында «Кыңгыраулар чыңы» («Звон колоколов») фильмы төшерелә.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии: Биогр. справ. К., 1975; Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007; Художники Татарстана: Справ. К., 2011.

**ШӘЙДУ́ЛЛИН** Рафаил Вәли улы (30.3.1960, Ульянов өлкәсенең Яңа Малыклы р-ны Лабит а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2004), проф. (2007), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2010). Рязаново совхоз-техникумын (Ульянов өлкәсенең Мәләкәс р-ны Рязаново а., 1979), Казан ун-тын (1987) тәмамлый. 1980–82 елларда Әлмәт торба з-дында эшли. 1990 нан ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында (2014 тән ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-ты), 1993 тән тарих һәм иҗтимагый фикер бүлеге мөдире, 2011–15 тә директорның 1 нче урынбасары, 2015 тән энциклопедистика үзәге мөдире. Бер үк вакытта, 1991 дән, Казан ун-тында, 2005 тән хәзерге заман ватан тарихы (2013 тән — Россия һәм якын чит илләр тарихы, 2017 дән — ватан тарихы) каф. профессоры. Хәзерге заман татар энциклопедистикасының фәнни концепциясен һәм фәнни-методик нигезләрен эшләүгә, Татарстан һәм татар халкының тарихы буенча энциклопедик басмалар, ш.и. рус һәм татар телләрендә күптомлы «Татарская энциклопедия» (1–6 т., 2002–2014), «Татар энциклопедиясе» (1–6 т., 2008–2019) булдыруга җитди өлеш кертә. Аның җитәкчелегендә һәм фәнни редакциясендә «Казакъстан татарлары: иллюстрацияле энциклопедик белешмәлек» («Татары Казахстана: иллюстрированный энциклопедический справочник», 2016), «Татарстан Республикасының юкка чыккан торак пунктлары» («Исчезнувшие населённые пункты Республики Татарстан», 2016), «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль символлары» («Государственные и муниципальные символы Республики Татарстан», 2017), «Казакъстан татарлары: иллюстрацияле кыскача энциклопедия» («Татары Казахстана: иллюстрированная краткая энциклопедия», 2017) һ.б. эшләнә. Хезмәтләре крәстияннәр сыйныфының 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөзнең 1 нче яртысындагы социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси тарихына; Татарстан тарихына, икътисадына һәм татар халкы, авыллары мәсьәләләренә карый. Россия һәм Татарстан тарихы буенча уку-укыту ярдәмлекләре авторы. Хәрби-тарихи фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (2011). Рус һәм татар телләрендә «Татарский энциклопедический словарь» (1999) һәм «Татар энциклопедиясе сүзлеге»н (2003) эшләүдә катнашканы өчен, ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2005). Медальләр, ТР Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.



Р.В.Шәйдуллин.

Хезм.: Крестьянские хозяйства Татарстана: проблемы и пути их развития в 1920–1928 гг. К., 2000; Крестьянство Татарстана: экономический и общественно-политический аспекты (1920–1929 гг.). К., 2004; Крестьянство Казанской губернии в 1860–1910-е гг.: в экономическом и социокультурном измерении. К., 2013 (автордаш); Центральные органы государственной власти и управления Татарстана (1920–2020 гг.): Науч.-справ. издание. К., 2017 (автордаш).

**ШӘЙДУ́ЛЛИН** Шамил Мортаза улы (1.8.1947, Тәтеш р-ны Берлек пос.), рәссам, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991), ТРның халык рәссамы (1997). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1968), И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын, Е.Е.Моисенко остаханәсен (1974) тәмамлый. 1977–80 елларда Х.Г.Якупов җитәкчелегендә СССР САнең Иҗат остаханәсендә шөгыльләнә. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980), Пётр I фән һәм сәнгать академиясе академигы (2005). Ш. картиналарында милли идеяләр яңарышы контекстында хәзерге рухилык проблемалары чагылыш таба. Иҗатының башлангыч чорында милли образлар барлыкка китергәндә акад. нәкышь мәктәбе традицияләрен үзләштерә. 1990 елларда модернистик сәнгать стилистикасына мөрәҗәгать итә, орма ясалышының татар халык сәнгатенә хас декоратив-орнаменталь һәм нәкышь принципларын, киңлекнең шартлы корылышын, символик-аллегорик тел, ассоциатив-абстракт образлар файдалана. Ш.ның күп кенә картиналарына киң сурәтләнгән сюжетлар, күп фигуралы композицияләр, динамик ритмнар хас. Күп картиналары — «Сабан туе» (1974), «Карт алмагач төбендә» (1978), «Яңа Сабан туе» циклы (1999–2006); героик тарихка — «Икмәк турында баллада» (1979), «Дөнья балаларына тынычлык» триптихы (1981), биш өлештән торган «Сугыш апофезы» (1997), «Сөембикә — Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе» (1998); рухи-әхлакый идеал эзләүгә — «Уяну» (1994), «Сабантуй бүләкләре» (1999), «Мәхәббәт һәм мәңгелек» (2009), «Рухка реквием — шагыйрь Г.Тукай истәлегенә» (2011) триптихлары һ.б. — татар авылы темасына багышлана.



Ш.М.Шәйдуллин.

Ш. иҗатында пейзаж аерым урын алып тора: «Кышкы әңгер-меңгер» (1975), «Кич, шомырт җыю» (1978), «Көтү кайта» (1979), «Әҗем мәчете» (1981), «Вакыт агышы» триптихы (1987), «Казан Кремле» (1993), «Көтү каршылаучылар» (2007), «Казан өстендә кич» (2011) һ.б. «Шагыйрь Г.Тукай портреты» (1975), «Тәрәзә янындагы кыз» (1975), «Савымчы» (1976), «Габдулла Тукай — халык шагыйре» триптихы (1986), «Халык артисты Айрат Арсланов портреты» (2012); «Миләшле натюрморт, автопортрет» (1974), «Чалыш көзгедәге автопортрет» (1979), «Чүлмәк белән автопортрет» (1980) һ.б.; «Чынаяк белән натюрморт» (1976), «Кызыл фонда вазадагы чәчәкләр» (2010) натюрмортлары; «Очыш», «Уяну» (икесе дә — 2004) композицияләре, «Кызыл шәфәкъ темасына абстракцияләр», «Татар мотивларына интерпретацияләр» (икесе дә — 2005) триптихлары авторы.

1974 тән бөтенсоюз — «Советлар иле яшь гвардиясе» (1976, 1978), «Яшь рәссамнар әсәрләре» (1977), «Татарстан АССР рәссамнары» (1980), «СССР — Ватаныбыз» (1982) (барысы да — Мәскәү); Нукус (1984), Баку (1985), Истанбул (Төркия, 1986), Уфа (1988) шәһәрләрендә, Сиэтл (АКШ, 1990), Истанбул (1993), Будапешт (1994), Дубай (Гарәп Әмирлекләре, 1995), Мәскәү (1996), Париж (2000), Баку (2008) шәһәрләрендә Татарстан рәссамнары; төбәкара — «Зур Идел» (1979–2011); бөтенроссия — «Совет Россиясе» (1980); халыкара — Г.Тукайның 125 еллыгына багышланган халыкара «Мәңгелеккә омтылам» (С.-Петербург, Мәскәү, 2011) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1978, 1983, 1985, 1987, 2000, 2008, 2015 тә Казанда уздырыла һ.б. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Казанда Г.Тукай әдәби музеенда һәм Яңа Кырлайдагы Г.Тукай музей-комплексында, И.В.Савицкий исем. Дәүләт музеенда (Нукус ш.), РФ һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана. «Асыл ил» әсәрләр циклы өчен (1995) ТРның Г.Ту-

кай исем. Дәүләт бүләге бирелә (2000). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Шамиль Шайдуллин. Живопись. Графика: Альбом. К., 2013.

*Әд.:* К о р з у х и н А. Золото Татарии // Дружба народов. 1982. № 4; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; К о ж е в н и к о в а Р. Меня бессмертие волнует... // Идель. 1999. № 8. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ШӘЙДУ́ЛЛИН** Шамил Нәфигулла улы (13.3.1939, Яңа Чишмә р-ны Сөлчәбаш а. — 1.1.2008, Чаллы), язучы. СССР Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Милиция академиясен тәмамлый (Ташкент, 1973). 1964 елдан Чистай сәгать заводында эшли. 1966–75 тә Ислотань шәһәрендә (Төрекмәнстан ССР) яши, эчке эшләр органнарында хезмәт итә. 1976 да Чаллыга күченеп килә һәм 1995 кә кадәр эчке эшләр органнарында эшли. Аның һөнәри эшчәнлеге детектив «Сөембикә шәмдәле эзеннән» (1992) романында һәм «Ваучерлардан келәп» («Кляп из ваучеров», Чаллы, 1993), «Иблис оҗмахы» (Чаллы, 2002) повестьларында, «Упкын өстендә» (Чаллы, 2005), «Караңгылык тантанасы» («Триумф тьмы», Чаллы, 2006), «Мәңгелек авырту» («Вечная боль», Чаллы, 2007) документаль повестьларында чагылыш таба.

**ШӘЙДУ́ЛЛИНА** Альбина Рәфис кызы (15.8.1969, Азнакай р-ны Буралы а.), педагог, пед.фән. д-ры (2011). Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1991), Сарман һәм Азнакай р-ннарының авыл мәктәпләрендә инглиз теле укыта. 2004 елдан Әлмәт нефть ин-тының чит телләр кафедрасында. Хезмәтләре техник белгечләр әзерләү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Интеграция образования и производства: современное состояние и перспективы. К., 2008; Подготовка специалистов технического профиля в условиях интеграции образования и производства: региональный опыт. К., 2009.

**ШӘЙДУ́ЛЛИНА** Нурсөя Нурулла кызы (11.4.1964, Әгерҗе р-ны Нарат а.), журналист, тәрҗемәче. ТРның атказ. матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре (2014). Казан ун-тының журналистика бүлеген (1986), Идел буе дәүләт хезмәте академиясен (2001) тәмамлый. 1986–1998 елларда «Азат хатын» (1992 дән — «Сөембикә»), 1998–1999 да «Татарстан» ж-лларында эшли. Фән, мәдәният, сәнгать әһелләре турында язмалары «Казан утлары», «Идел», «Ватаным Татарстан», «Сәхнә» басмаларында дөнья күрә. Күренекле шәхесләрнең иҗади портретлары остасы буларак таныла. 1999–2014 тә ТР Президенты матбугат хезмәтендә баш киңәшче. 2014 тән — ТР Дәүләт Киңәшчесе М.Ш.Шәймиев ярдәмчесе. «Минтимер Шәймиев» (М., 2016) китабы автордашы. Р.Хәкимовның «Татарский дух» («Татар рухы», 2007), С.Ш.Шәймиеваның «В тени Минтимера» («Минтимер күләгәсендә», 2008), Р.Минһаҗев, И.Кыямовның «Президент М.Ш.Шаймиев: социально-психологический портрет» («Президент Минтимер Шәймиев: социаль-психологик портрет», 2012) һ.б. китапларын татар теленә тәрҗемә итә. Журналистика һәм масс-медиа өлкәсендә «Бәллүр каләм» — «Хрустальное перо» респ-ка конкурсы лауреаты (2017). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘЙМӘРДА́НОВ** Галим Шәймәрдан улы (20.3.1917, Казан губ., Мамадыш өязе Сатыш а. — 30.10.2006, Казан), слесарь-механик, Соц. Хезмәт Герое (1977). Казан авиакомб-тының һөнәри-техник мәктәбен тәмамлый (1934). 1935–87 елларда Казан язу җайланмалары з-дында эшли, аеруча катлаулы җитештерү бурычларын үти. Үзенең шәхси гарантияле сыйфат клеймәсе була. 9 нчы (1971–75), 10 нчы (1976–80) һәм 11нче (1981–85) бишьеллык планнарын вакытыннан алда төгәлли, берничә тапкыр соц. ярышларда җиңүче була. 13 рационализаторлык тәкъдимнәрен эшли (1971–75), аларны гамәлгә кертү югары икътисади нәтиҗә бирә. Герой исеме яңа техника җитештерүдә ирешкән уңышлары өчен бирелә. Бөек Ватан сугы-













Ш.М.Ш ә й д у л л и н. 1. «Карт алмагач төбендә». 1978. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Сабантуй бүләкләре» триптихы. Үзәк өлеш. 1999. ТР Милли китапханәсе; 3. «Кырдан кайту». 1987. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. «Г.Тукай – халык шагыйре» триптихы. «Тагын юлга, яки ятимлек» исемле үзәк өлеше. 1986. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. «Җиләс иртә». 2009; 6. «Вәсилә». 1985.


Г.Ш. Шәймәрданов.


З.Ш. Шәймәрданов.


Ш.Ш. Шәймәрданов.

шында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, «Почёт билгесе», 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр, ш.и. ВДНХның ике бронза медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003. *М.Ж.Гаитов.*

**ШӘЙМӘРДӘ́НОВ** Зәки Шәймәрдән улы (13.7.1923, Лаеш кантоны, хәзер Балык Бистәсе р-ны Биектау а. — 29.1.1967, шунда ук), Сов. Союзы Герое (13.9.1944), гв. өлкән лейтенанты. Хәзерләүләр оешмасында эшли. 1942 елның мартыннан Кызыл Армиядә. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 32 нче гв. артиллерия полкында туп төзәүче (5 нче гв. армиясенең 13 нче гв. укчы дивизиясе). Дала, 2 нче һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Корсунь-Шевченко (1944) һәм Сандомир-Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 6 гыйнварында Субботица авылы (Корсунь-Шевченко шәһәре тирәсе, Украина) янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: сугыш барышында туп янында ялгыз кала, турыдан-туры төзәп дошманның 2 танкын һәм 4 транспортёрын сафтан чыгара, укчыларга урнашкан позицияләрне тотып калырга ярдәм итә. Сугыштан соң запаста. КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый (Мәскәү, 1946), КПССның Кызыл Йолдыз (1946–59) һәм Балык Бистәсе (1959–67) районнары ком-тларында инструктор булып эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Биектау һәм Балык Бистәсе авылларында Ш.ка бюст куелган һәм мәктәптә музей ачылган, Балык Бистәсе авылындагы бер урамга аның исеме бирелгән.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ф а т т а х о в Г.М. «Это имя ты должен знать» (Герой Советского Союза З.Ш.Шаймарданов) // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2013. № 1/2. (70–71); Ф а т т а х о в Г.М. Трудные дороги победы. К., 2014. *Г.М.Фәттахов.*

**ШӘЙМӘРДӘ́НОВ** Рафаэль Галимҗан улы (12.7.1948, Бөгелмә ш.), химик физика, икътисад өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1993), проф. (1998), полковник (1991). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), Черкесск химия з-дында эшли. 1973–92 елларда РФ Кораллы көчләрендә хезмәт итә. 1991 дә РФ Хөкүмәте каршындагы Финанс академиясен тәмамлый. 1992–94 тә РФ Хөкүмәте каршындагы Бөтенроссия хәрби хезмәткәрләренең социаль гарантияләре фонды ген. директоры. 1994–97 дә Бөгелмә шәһәре хакимияте каршындагы Икътисади-социаль тикшеренүләр үзәге директоры урынбасары, 1997 дән — Казан технол. ун-тының Бөгелмә гомуми техник ф-лы янындагы шул ук исемдәге үзәк директоры урынбасары. Хезмәтләре операцияләр теориясенә, икътисадта матем. алымнарга карый. Ш. мәгълүмат чикләнгәнлеге шартларында ихтималлыклы характеристикаларны, ихтималлыклы модельләштерүне тикшерү алымнарын эшли. Катлаулы икътисади процессларны һәм системаларны анализлауның гамәли бурычларын хәл итү өчен инде алдан эшләнгән теоретик нигезләмәләрне куллану мөмкинлеген тикшерә. Бөгелмә сәнәгать пр-тиеләрен кризистан чыгару максатында аларны реструктуризацияләү алымнарын, оешкан җинаятьчелек б-н көрәшү формаларын һәм алымнарын тәкъдим итә. Бөгелмәдә яшәүчеләрне җир астындагы чыганаклардан су б-н тәэмин итүгә юнәлдерелгән «Чиста су» проектын эшләүдә катнаша. ТРдагы табигый битумнарны эшкәртү схемаларын техник һәм икътисади җәһәтләрдән нигезли. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Методы военно-научных исследований в задачах разработки вооружения: В 2 ч. М., 1996.

**ШӘЙМӘРДӘ́НОВ** Рәфис Хәсән улы (12.8.1955, Зәй р-ны Әхмәт а.), педагог, пед. фән. д-ры (1998), проф. (2000). Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1979). 1977 елдан Зәй р-нының Түбән Биш урта мәктәбендә физика һәм математика укыта, 1982 дән Алабуга пед. ин-тында, 2001 дән Сургут пед. ин-тының гомуми пед. кафедрасында (Төмән өлкәсе). Хезмәтләре укытучының шәхси һөнәри үсеш мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Технология интенсивного развития личности учителя высшей квалификации. К., 1997; Концептуальные основы личностно ориентированного педагогического процесса. Сургут, 2003.

**ШӘЙМӘРДӘ́НОВ** Фәрагать Әхмәт улы (20.2.1929, Бөгелмә кантоны Чалпы а. — 24.8.2008, Уфа ш.), электрон идарә системалары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1975), проф. (1977), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1990), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1982), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1986). Мәскәү энергетика ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Уфа пр-тиеләрендә эшли: 1953–56 елларда Уфа аппаратура з-дында (инженер-сынаучы, мастер, әйдәп баручы конструктор), 1956–72 дә «Молния» тәҗрибә КБда әйдәп баручы конструктор. 1972–98 дә Уфа авиация техник ун-тында: авиация приборлары төзү каф. мөдире, шул ук исемдәге ф-т деканы (1977 тән). Газ турбиналы двигательләрне электрон идарә итү системалары өлкәсендә фәнни мәктәпкә нигез сала. Двигатель режимы б-н идарә итүнең тәүге цифрлы системасын эшләүчеләрнең берсе (гражданнар һәм хәрби авиациядә кулланыла). Уйлап табуга 80 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Системы автоматического управления двигателями летательных аппаратов. М., 1973; Синтез систем автоматического регулирования методом порядкового отображения. М., 1983; Применение микро-ЭВМ в задачах автоматизации промышленных установок. Пермь, 1986.

**ШӘЙМӘРДӘ́НОВ** Шәйгәрдән Шәймәрдән улы (1890 елның сентябре, Уфа губ., Минзәлә өязе Иске Байсар а. — 1940 ның гыйнвары, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе. Тышкы сәүдә академиясен тәмамлый (1933). 1911 дән хәрби хезмәттә, Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышларында катнаша. 1918 дән хакимият-хуҗалык һәм партия эшендә: Минзәлә кантон советы рәисе урынбасары (1918–21), шул ук советның башкарма ком-ты рәисе (1921–1924), бер үк вакытта, 1921 дән, Минзәлә кантоны хәрби комиссары. 1920 дә Татарстан АССРның чикләрен билгеләү буенча ведомствоара комиссия эшендә катнаша. 1924 тән ТАССР ҮБК рәисе урынбасары, 1925 тә ҮБК рәисе, 1927–28 дә ТАССР ХКС рәисе. Идел буе ҮБКлары рәисләренә юлланган (ВКП(б) ҮКна адреслана) «Унлык хаты» авторларының берсе. Хатта Идел буе төбәге милли респ-калары һәм өлкәләре икътисадының артыгы б-н үзәкләштерелүенә һәм аларның этник үзенчәлекләре исәпкә алынмавына протест белдерелә. 1928 дән Мәскәүдә: ВКП(б) ҮКның җаваплы инструкторы (1928–30), РСФСР Финанслар халык комис-ты коллегиясе әгъзасы, «Совафганторг» рәисе урынбасары, СССРның Тува Халык Респ-касындагы сәүдә вәкиле (1935–37). 1937 дән Тышкы сәүдә халык комис-тында, 1938–39 да Бөтенсоюз «Союзпушнина» берләшмәсе башлыгы урынбасары. Милли кадрларны җитештерүгә һәм респ-када эш башкару процессын татар теленә күчерүгә зур өлеш кертә. ТАССРның беренче Конституциясе проектын эшләүгә катнаша (1926). Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* И м а м о в В. Хөкүмәт башлыгы Шәйгәрдән Шәймәрдәнов // Актанышым — ак илем. К., 2010; К а с и м о в Г. Шаймарданов Шайгардан Шаймарданович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2. *Ф.Г.Миңнеханов.*

**ШӘЙМИ́ЕВ** Минтимер Шәрип улы (20.1.1937, Калинин, хәзер Актаныш р-ны Әнәк а.), дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, ТРның беренче Президенты (1991–2010). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Мөслим ремонт-техник станциясендә инженер, баш инженер, 1962–67 елларда Минзәлә «Сельхозтехника» районара берләшмәсе директоры. 1967–69 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында: инструктор, а.х. бүлеге мөдире урынбасары; 1969–83 тә ТАССР мелиорация һәм су хуҗалыгы министры. 1983–84 тә ТАССР МС рәисенең 1нче урынбасары, 1984–85 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре, 1985–89 да ТАССР МС рәисе, 1989–90 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты 1нче секретаре. 1990–91 дә ТССР ЮС рәисе. 1991 нең 12 июненнән ТР Президенты (1996



М.Ш. Шәймиев. 1990.

ның мартында икенче, 2001 нең мартында өченче, 2005 нең мартында РФ Президенты В.В. Путин тәкъдиме б-н ТР ЮС тарафыннан дүртенче срокка сайлана). 2010 нан беренче тапкыр гамәлгә куелган ТР Дәүләт Киңәшчесе вазифаларын башкара, закон проектлары кертү хокукына ия, ТР Дәүләт Советының гомерлек әгъзасы.

1975–90 да ТАССР ЮС депутаты, 1990–91 дә ТАССР халык депутаты, КПСС ҮК әгъзасы. 1986–90 да РСФСР ЮС депутаты, 1989 дан СССР халык депутаты. 1994–2001 дә РФ Федераль Җыенының Федерация Советы әгъзасы. 2000–01 дә РФ Дәүләт Советы Президиумы, Федерация эшләре, федератив килешү һәм региональ сәясәт буенча ком-т әгъзасы. 2001–11 дә «Бердәм Россия» партиясенең Югары советы рәистәше.

1970–80 елларда Ш.нең актив катнашы б-н респ-када сугару һәм киптерү системаларын төзү һәм а. х.ның яңа тармагын — сугарулы игенчелекне булдыру буенча киң колачлы эш җәелдерелә, бу исә терлек азыгы җитештерүне арттыруга, халыкны респ-када җитештерелгән яшелчә һәм бәрәңге б-н тәэмин итүгә юл ача.

1980 еллар ахыры — 1990 еллар башында илдә иҗтимагый-сәяси стройны тирәннән үзгәртеп кору процесслары, Татарстанның Россия составында булган килеш үзбилгеләнү хәрәкәте көчәя барган, татар халкы мәдәнияте яңарышы шартларында Ш. үзен алдан күрүчән дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе буларак күрсәтә, респ-каның сәяси һәм икътисади суверенлыгы ныгыун, аның социаль-икътисади һәм мәдәни алгарышы программасын гамәлгә ашыруны тәэмин итә, Татарстан халыкларын һәрьяклап үстерү, тотрыклылык һәм милләтара татулык саклау, якын һәм ерак чит илләр б-н багланышларны киңәйтү сәясәтен үткәрә. Ш. инициативасы б-н 1990 ның 30 августында «*Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында декларациясе*» кабул ителә, 1992 нең 21 мартында респ-каның дәүләт статусы буенча референдум үткәрелә, аның нәтиҗәсеннән чыгып, 1992 нең 6 ноябрендә *Татарстан Республикасы Конституциясе* кабул ителә. 1994 нең 15 февралендә М.Ш.Шәймиев һәм РФ Президенты Б.Н.Ельцин РФ һәм ТРның «*Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында үзара эшләр алмашу һәм вәкаләтләр бүлешү турында*» *Шартнамәсенә* кул куялар. 2007 нең 26 июнендә РФ Президенты В.В.Путин һәм Ш. «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында»гы яңа Шартнамәне имзалыйлар. 2007 нең 24 июлендә Шартнамә РФ Законы буларак раслана, шулай итеп РФ дәүләт институтлары эшчәнлегенең федератив принциплары ныгытыла.

Ш. җитәкчелегендә респ-када базар икътисадына «салмак керү» сәясәте уңышлы рәвештә уздырыла. Нәтиҗәдә, машина төзү, нефть һәм нефть химиясе сәнәгате, электр энергетикасы h.б.ның төп пр-тиеләре респ-ка карамагында калдырыла; яңа эре проектлар гамәлгә ашырыла; Түбән Кама шәһәрендә «*ТАИФ-НК*», «ТАНЭКО» нефть эшкәртү һәм нефть химиясе з-длары, Чаллы һәм Алабуга шәһәрләрендә «Sollers» автомобиль з-длары комплексы төзелә; торак пунктларны тоташ газлаштыру программасы башкарыла. Бу респ-ка халкының, бигрәк тә авылларда яшәүчеләрнең көнкүреш шартларының тамырдан яхшыруына китерә. 1995 нең октябрендә Ш. тарафыннан «Тузган торак фондында яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту һәм тузган торак кварталларын реконструкцияләү буенча чаралар турында» Указ имзалана (к. *Тузган торакны бетерү программасы*, 1996–2004 елларга исәпләнә) программалары башкарыла. Аның буенча Казанда һәм респ-каның башка шәһәрләрендә 42,5 меңнән артык гаилә (якынча 245 мең кеше) барлык уңайлыклары булган йортларга күчерелә. 2000 елларда респ-када матди-техник базаны ныгыту, мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль-мәдәни өлкә учреждениеләрен кадрлар б-н тәэмин итүне камилләштерү буенча иң мөһим милли проектлар гамәлгә ашырыла.

Ш. — 2005 тә Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүне оештыручыларның берсе. Бәйрәмгә әзерлек чорында шәһәрнең тарихи үзәген, шәһәр инфраструктурасы объектларын үзгәртеп төзү буенча киң колачлы эшләр алып барыла, метрополитенның беренче 5 станциясе файдалануга тапшырыла, Казан Кремле капиталь рәвештә реконструкцияләнә һәм реставрацияләнә (заманча «*Колшәриф*» дини, гыйльми, мәдәни-агарту комплексы-мәчете төзелә, Благовещение кафедраль соборы реставрацияләнә, «*Казан Кремле*» тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгы ачыла). 2000 нең ноябрендә Казан Кремле ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелә. Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткән



М.Ш.Шәймиев һәм В.В.Путин.
Казан. Кремль. 2012.

көннәрдә (2005, 26–27 авг.) биредә БДБ илләре башлыклары Советы саммиты һәм РФнең 81 субъекты башлыклары катнашында РФ Дәүләт Советы утырышы уздырыла. 2008 дә ТР башкаласы студентларның XXVII Бөтендөнья спорт — 2013 елгы Халыкара җәйге Универсиаданы үткәрү хокукын алуга ирешә. Әлеге күренекле чараның уңышлы узуы дөньяда югары бәяләнә. Ш. президент булган елларда Казан Евразиянең гомумтанылган социомәдәни һәм эшлекле үзәкләрнең берсенә әверелә, респ-ка Россиянең инвес-



БДБ дәүләтләре башлыклары Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә. Казан Кремле. 2005.

тицион активлык һәм торак төзелеше ягыннан югары дәрәҗәдәге, икътисади яктан иң нык үскән төбәкләре исәбенә керә. 1992 дә Ш. җитәкчелегендә *«Бөтендөнья татар конгрессы»* оештырыла.



М.Ш. Шәймиев (уңда) һәм ККП ҮК Генераль секретаре, КХР Рәисе Ху Цзинь Тао Кытай делегациясенең Казанга визиты вакытында. 2007.

Ш. алып барган төпле, прагматик сәясәт татар халкының дәүләтчелеген торгызу, респ-када социаль, милләтара һәм динара тотрыклылык өчен хәлиткеч алшартлар тудыра. Аның Президент вазифасындагы эшчәнлегенең иң мөһим нәтиҗәсе булып Россиядә һәм бөтен дөньяда милләт буларак татарларга карата ихтирамлы мөнәсәбәт урнаша.



М.Ш. Шәймиев (уңда) һәм Төркия Президенты Абдулла Гюль. Казан. 2009.

Ш. — «Мәдәни мирас: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәре» проектын эшләүгә башлангыч бирүче; 2010 ның мартыннан аның башлангычында оештырылган Татарстан Респ-касы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу буенча «Яңарыш» фондының попечительләр советы рәисе; Казан, Борынгы Болгар һәм Зөя утрау-шәһәрчегендәге тарих-мәдәният объектларын реставрацияләү, реконструкцияләү һәм төзү, аларда федераль әһәмияткә ия музей-саклаулыклар оештыру эшләрен координацияли.



М.Ш. Шәймиев һәм АКШның Дәүләт секретаре Хиллари Клинтон аның РФ гә визиты көннәрендә. Казан. 2009.

Ш. инициативасы б-н Болгар шәһәре дөнья мәдәнияте өчен универсаль кыйммәткә ия ядкарь буларак ЮНЕСКО ның Бөтендөнья мирасы объектлары исемлегенә кертү өчен тәкъдим ителә, 2014 нең 23 июнендә әлеге оешманың 38 нче сессиясендә бу хакта уңай карар кабул ителә. Ш. тәкъдиме, РФ Президенты В.В.Путин һәм ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов булышлыгы б-н Болгар шәһәрендә Болгар ислам академиясе төзелеп, 2017 дә эшли башлый. Респ-каның Тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу фондының попечительләр советы рәисе буларак, 2015 нең ноябреннән Казан Изге ана иконасы соборын төзүне җитәкли.



М.Ш. Шәймиев һәм Р.Н. Миңнеханов Зөядә. 2011.

Ш. Ленин ордены (1966), Хезмәт Кызыл Байрагы (1971), Октябрь Революциясе (1976), Халыклар дуслыгы (1987) орденнары, Россия дәүләтчелеген ныгытуга, илне социаль-икътисади үстерү буенча стратегик бурычларны үтәүгә, халыклар арасындагы дуслык һәм хезмәттәшлекне ныгытуга зур өлеш кертүкә өчен 1 нче, 2 нче, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, РФнең һәм күп кенә чит илләрнең бүләкләре б-н бүләкләнә. 2017 дә ватан һәм халык алдындагы аерым казанышлары өчен РФ Хезмәт Герое исеменә лаек була. 2017 елда Ш.кә ЮНЕСКОның мәдәниятләр арасында диалогны ныгыту буенча махсус илчесе исеме бирелә.

Х е з м.: Татарстан — прогресс через стабильность = Татарстан тотрыклы үсештә: Избр. статьи, выступления, материалы пресс-конф., приветствия: В 11 кн., К., 2001–10.

*Әд.:* М у с т а ф и н Р.А., Х а с а н о в А.Х. Первый Президент Татарстана Минтимер Шаймиев (Штрихи к политическому портрету). К., 1995; Бухараев Р.Р. Президент Минтимер Шаймиев и «модель Татарстана»: Очерк полит. творчества. СПб. — Лондон, 2000; ш у л у к. Татарстан: «Мы — можем!». Президент Минтимер Шаймиев и созидательность здравого смысла. Уилтс, 2007; О в р у ц к и й Л.М. Беседы с Минтимером Шаймиевым. К., 2013; Ц ы б у л ь с к и й И., Ш а й д у л л и н а Н. Минтимер Шаймиев. М., 2016.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**ШӘЙМОРА́ТОВ** Миңлегали Минһаҗ улы (15.8.1899, Уфа губ., Уфа өязе Биштәкә а. — 23.2.1943, Украина ССРның Ворошиловград өлкәсе Ивановка р-ны Петровское а.), генерал-майор (1942). М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне тәмамлый (1934). 1919 елдан Кызыл Армия сафларында. Гражданнар сугышында катнаша: адмирал А.В.Колчак армиясенә каршы, С.М.Будённыйның Беренче атлы армиясендә, Төркестан фронтында сугыша. 1925–31 дә БҮБК исем. берләшкән хәрби мәктәптә курс командиры; 1931–41 дә Кызыл Армия Ген. штабының разведка идарәсе органнарында. Бер үк вакытта Төркиядә хәрби атташе (1934–35), Гоминьдан хөкүмәте каршындагы хәрби ком-т киңәшчесе (1936–37), Кытайда хәрби атташе (1938–40). 1941 дә Кремльне саклау часте — 1 нче Аерым кавалерия полкы командиры (полковник), Волоколамск яныңдагы сугышларда катнаша. 1942 дән хәрби часть башлыгы һәм Сталинград, Украина өчен барган сугышларда катнашкан 112 нче (1943 тән — 16 нчы) Башкорт кавалерия дивизиясе командиры. Сугышта һәлак була. Ике Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г у м е р о в Ф.Х. Генерал Шаймуратов. Уфа, 1999; Л у р ь е В.М., К о ч и к В.Я. ГРУ: дела и люди. СПб., 2002.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ШӘЙМОРА́ТОВ** Рафат Вафа улы (19.5.1941, Сталинабад ш., Таҗикстан ССР — 2005, Казан), математик, техник фән. д-ры (1985), проф. (1988). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1963), «ТатНИПИнефть»тә (Бөгелмә ш.) эшли. 1969 елдан Гомель ун-тында (Беларуссия ССР). 1995–2003 тә Казан пед. ун-тының хисаплау математикасы каф. мөдире. Хезмәтләре нефть чыганакларының фильтрация процессларын тикшерүгә карый. Нефтьне карбонат коллекторларыннан чыгару технол. күрсәткечләрен хисаплау нигезләрен һәм алымнарын эшли.

Х е з м.: Гидродинамика нефтяного трещиноватого пласта. М., 1980; Основы численного анализа (татар телендә). К., 2001.

**ШӘЙМОРА́ТОВА** Әсма Сабир кызы (9.12.1910, Уфа губ., Уфа өязе Арыслан а. — 11.1.1992, Уфа ш.), җырчы (сопрано), БАССРның атказ. артисты (1950). 1932 елда Башкорт сәнгать техникумын тәмамлый, 1933–42 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Башкорт опера студиясендә (М.Владимирова классы) укый (бүленеп). 1942–48 дә Башкорт опера һәм балет театры солисты, Маргарита («Фауст», Ш.Гуно), Татьяна («Евгений Онегин», П.Чайковский), Марфа («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Айсылу («Ашказар», А.Эйхенвальд) һ.б. партияләрне башкара. 1948–50 дә — Татар филармониясе (1949 да С.Сәйдәшевнең концерт группасы составында Уфа, Оренбург, Ташкент, Алма-Ата шәһәрләре буйлап гастрольләрдә катнаша), 1950–60 та — Башкорт филармониясе солисты. Ш.ның концерт репертуарын башкорт һәм татар композиторлары әсәрләре, башкорт һәм татар халык көйләре тәшкил итә.

**ШӘЙМОРЗА́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Тилчә елгасы буенда. 2010 елда 293 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына, 1950 еллар уртасына кадәр Яңа Шәйморза исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә (лашман хезмәтен үти), игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, 10 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1242,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Иске Суыксу волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 537, 1897 дә — 862, 1913 тә — 1185, 1920 дә — 1146, 1926 да — 1120, 1938 дә — 1256, 1949 да — 1041, 1958 дә — 890, 1970 тә — 1000, 1979 да — 886, 1989 да — 337, 2002 дә — 296 кеше.

**«ШӘЙМОРЗА́»**, Чүпрәле р-нындагы а.х. пр-тиесе. 1930 елда Иске Шәйморза авылында Будённый исем. к-з буларак оештырыла. 1944 тә аның составыннан мөстәкыйль Сталин исем., Тукай исем., «Татарстан» к-злары аерылып чыга, 1950 дә кабат Сталин исем. к-зга берләштереләләр. 1958 дә хуҗалыкка Киров исем. (Иске Шәйморзаның бер өлеше) һәм «Кызыл Сабанчы» (Кече Шәйморза а.) к-злары кушыла. 1961 дә хуҗалык 22 нче партсъезд исем. к-з итеп үзгәртелә, 1994 тә «Шәйморза» крәстиян хуҗалыклары ассоциациясе, 2004 тә ҖЧҖ, 2008 дә Әбдриев исем. «Шәйморза» АҖ. Иске Шәйморза (үзәк утар) һәм Кече Шәйморза авылларын үз эченә ала. А.х. житештерүендә 214 кеше эшли (2012); а.х. файдалану җирләренең мәйданы 6777 *га*. Төп тармаклары — бөртекле ашлык, шикәр чөгендере, сөт, ит җитештерү. 2012 дә 8131 *т* бөртекле ашлык, 8300 *т* шикәр чөгендере, 1510 *т* сөт, 139 *т* ит җитештерелә. Бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 33 *ц*, шикәр чөгендере 290 *ц* тәшкил итә. А.х. продукциясе җитештерүдәге югары күрсәткечләре өчен хуҗалык КПСС ҮК, СССР ЮС Президиумы, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның Кызыл байрагы (1967), СССР А.х. һәм хәзерләүләр министрлыгының Кызыл байрагы (1973), РСФСР МС һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл байрагы (1977, 1979, 1982, 1983, 1986), СССР ЮС Президиумы, СССР МС, ВСЦСПСның (1972, 1987) Мактау грамоталары, СССР ВДНХсының дипломнары (10 тапкыр) б-н бүләкләнә. Хуҗалык хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. РСФСР, ТАССР атказ. а.х. хезмәткәре — 9, Соц. Хезмәт Герое — 1 кеше; Ленин ордены — 6, Октябрь Рев-циясе ордены — 2, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 11, Халыклар дуслыгы ордены — 1, 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны ордены — 1, «Почёт билгесе» ордены — 15, СССР ВДНХсының медальләре, ш.и. алтын медаль — 1, көмеш медаль — 5, бронза медаль — 8 кешегә бирелә. Пр-тие җитәкчеләре арасында — Ә.Ш.*Әбдриев* (1955–88), Р.Ә.Әбдриев (1988 дән).

*И.Н.Афанасьев.*

**ШӘЙХЕЛИСЛА́М** (гарәпчә شيخ الاسلام — карт кеше, әйдәп баручы, рухи юлбашчы), исламда аеруча хөрмәтле җитәкче титулы. 10 йөздән очрый, 15–16 йөзләрдә Госманлылар империясендә дәрәҗәсе күтәрелә (дәүләт идарәсе иерархиясендә икенче урын били). БДБ илләрендә «Ш.» титулын йөртүчеләр — Россия мөселманнарының Үзәк Диния Нәзарәте рәисе Т.Таҗетдин, Кавказ мөселманнары Диния Нәзарәте җитәкчесе А.Пашазадә. Ш.у.к.: *Шәех.*

**ШӘЙХЕЛИСЛА́МОВ** Рәис Фалих улы (24.10.1951, Мөслим р-ны Мөслим а.), педагог, икътисадчы, халык мәгарифе эшлеклесе, пед. фән. канд. (1990), икътисад фән. д-ры (2002), проф. (2003). Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Тукай р-нында матем. укыта, мәктәп директоры була. 1988 елдан Чаллы пед.ин-тында. 1992 дән Чаллы хакимияте мәгариф идарәсе башлыгы, 1997 дән Казан ун-тының Чаллы ф-лы директоры. 2004 тән ТР мәгариф министры, 2007–11 дә ТР Мәгарифне үстерү ин-ты ректоры. Хезмәтләре халык мәгарифе б-н идарә итү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Целевой подход к управлению городским общеобразовательным комплексом. К., 2002.

**ШӘЙХЕЛИСЛА́МОВА** Мария Владимировна (25.2.1958, БАССРның Янавыл пос.), физиолог, биол. фән. д-ры (2008). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1981). Казанның Мәскәү һәм Идел буе р-ннарының сан.-эпид. станцияләрендә табиб булып эшли. 1986 елдан Казан гуманитар-пед. ун-тында, 2011 дән Казан ун-тының Физкультура һәм тернәкләндерү медицинасы ин-тында. Хезмәтләре 7–15 яшьлек балаларның физик һәм акыл хезмәтенә нейроэндокрин яраклашу механизмнарын өйрәнүгә карый. Ш. балалардагы яраклашу эшчәнлегенең үсеп килүче организмның метаболизм һәм адаптация ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән бөер өсте бизләре кабыгының симпат-адренал системаларының үзара бәйләнешле реакцияләре б-н тәэмин ителүен исбатлый.

Х е з м.: Гормональный статус и вегетативный тонус у детей 7–15-летнего возраста. К., 2008 (автордаш).

**ШӘЙХЕТДИ́НОВ** Әсхәт Шәйхетдин улы (1.12.1932, Мәскәү өлкәсенең Клин ш. – 7.4.2014, Казан), спортчы, тренер (грек-рим көрәше, ирекле көрәш, самбо), СССРның спорт остасы (1955), РСФСРның атказ.тренеры (1970), ТАССР, Россиянең атказ. физик культура хезмәткәре (1986, 2003). Омск физик культура ин-тын тәмамлый (1964). Спорт б-н 1946 елда «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә (Казан) шөгыльләнә башлый, тренерлары — Н.И.*Моряшичев*, В.П.Рыбалко (1951–54). РСФСР (1955, шәхси беренчелектә), СССР (1955, команда беренчелегендә) чемпионы, СССР чемпионатында бронза медаль ала (1955), РСФСР халыклары Спартакиадасында (1956), халыкара турнирларда (1954–57) җиңүче. Украина (1953), РСФСР (1955–58), СССР (1955–57) җыелма командалары әгъзасы. 1958 дән Казанда: урта мәктәптә (1958–60), «Спартак» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан советында (1960–70), Казан а.х. ин-тында (1970–94), ТР Спорт һәм туризм дәүләт ком-тының Үзәк СКда (1994–97), РФ Эчке эшләр министрлыгының юридик ин-тында (1997–2003) эшли. ТАССР (1955–61), РСФСР (1960,1967), СССР (1960, 1964) җыелма командаларында тренер була. Шәкертләре арасында — РСФСР халыклары спартакиадаларында, РСФСР, СССР, Европа чемпионатларында, дөнья кубогына ярышларда җиңүчеләр һәм медальләр алучылар: В.И.Капошин, В.Ф.*Маркелов*, И.Миңнуллин, Г.И.Митин (Бехерман). Бөтенсоюз категорияле (1959, ирекле һәм классик көрәш) һәм халыкара категорияле (1995, гер спорты) судья. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы, «Россиядә Олимпия хәрәкәтен үстерүдәге казанышлары өчен», «Милли көрәшне үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгеләре б-н бүләкләнә. Казанның мактаулы гражданы (2007). 2005 тән Ә.Ш.Шәйхетдинов призына билбаулы көрәш буенча Бөтенроссия турниры уздырыла.

**ШӘЙХЕТДИ́НОВ** Вәкил Гыйлем улы (4.5.1951, БАССРның Бүздәк р-ны Капәй-Кобау а.), нәкышьче, монументалист, БРның атказ. рәссамы (1999), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2010). Уфа сынлы сәнгать уч-щесен (1973), Уфа сәнгать ин-тын, Р.М.Нурмөхәммәтов остаханәсен (1980) тәмамлый. 1983–91 елларда Уфада Башкорт иҗат-җитештерү комб-тында рәссам була. Рәссамнар берлеге (1991), ЮНЕСКО каршындагы халыкара рәссамнар ассоциациясе әгъзасы (2006). Ш.ның авторлык иҗат-идея концепциясе форма буенча ачык һәм кыска, образларда төсләрне тиешле файдалануда чагылыш таба. Аның сәнгатьчә тасвирлавына монументалы гомумиләштерү, киңлекне масштаблы хәл итү, форманы ритмик оештыру хас. Тематик картина, портрет, пейзаж, натюрморт жанрларында эшли: «Апокалипсис» (1982), «Әти портреты»; «Уфа капкалары», «Яңгырдан соң» триптихлары (барысы да — 1992); «Әссәламегаләйкем», «Җомга намазы», «Аллаһы әкбәр», «Мәгарә», «Караңгы төшү» (барысы да — 1992), «Рамазан», «Бабайга багышлау» (икесе дә — 1993), «Моң», «Тере җир», «Ике тапкыр Советлар Союзы Герое Муса Гәрәев портреты» (барысы да — 1994), «Анага багышлау» (1995) һ.б. Хаҗ кылганнан соң (1996), мөселман сәнгате образлы стилистикасында иҗади эзләнүләрен үстерә. Иудаизм, христианлык һәм ислам тарихына багышланган картиналар сериясен иҗат итә — «Икърар» (1997); Болгар ш. — «Кече манара», «Җамигъ мәчет янында уйланулар», «Кара пулат», «Төньяк төрбә», «Көньяк төрбә» барысы да — 1996); «Аллаһы әкбәр» полиптихы (1996), «Дудаил» картинасы (1999), «Нур тавында Мөхәммәд пәйгамбәргә вәхи иңү» (2000) һ.б. Акварель б-н эшләнгән «Мәккә күренешләре», «Болгар күренешләре» (икесе дә — 1996) серияләре



И.Г. Шәйхетдинов.



Н.Ш. Шәйхетдинов.

авторы. 2000 нән портрет жанрына мөрәҗәгать итә, замандашлары, татар халкының күренекле вәкилләре — ТРның беренче Президенты М.Шәймиев, ТР Президенты Р.Миңнеханов, офтальмолог Э.Мулдашев, драматург Т.Миңнуллин, шагыйрь Р.Вәлиев, язучы Р.Батулла, актёрлар Р.Шәрәфиев, Ә.Шакиров, җырчылар И.Шакиров, Ф.Кудашева, мөфти Т.Таҗетдин һ.б. образлар галереясын иҗат итә. «Казан» милли мәдәният үзәге музее экспозициясендә «Төрки дөньяның барлыкка килүе» дивар панносы (бизәк) (2000, автордаш Р.Миңнебаев), Уфадагы «Нур» татар драма театры дивар мозаикасы (2009) авторы.

1972 дән Уфада Башкортстан АССР рәссамнары; төбәкара — «Урал-2003», «Урал рәссамнары» (Чиләбе ш., 2003, 2008), «Зур Идел» (2011); бөтенроссия — «Җиңүнең 40 еллыгына» (1990), «Мәскәүнең 850 еллыгына» (1997); «Россия рәссамнары» (Мәскәү, 2004), «Россия монументалистлары» (Ярославль ш., 2008); халыкара — (София ш., Болгария, 1988), ТЮРКСОЙ (Әнкара, Төркия, 2001; Алма-Ата, 2002) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1982 (Башкортстан АССРның Октябрьский ш.), 1993, 1996, 1998, 1999, 2001, 2003, 2007, 2011 (Уфа ш.), 1997 (Болгар ш.), 1998, 2009, 2012 (Казан), 1998 (Мәскәү). Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкортстан Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, «Вилга» (Болгария) галереясында саклана. Медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Вакиль Шайхетдинов. Икърар (слово о религии). Живопись: Каталог. Уфа, 1997; Фенина Э.П. Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ШӘЙХЕТДИ́НОВ** Владимир Шамил улы (21.8.1937, Ленинград), юрист, юридик фән. д-ры (1986), проф. (1988). Казан ун-тын тәмамлый (1960). 1960–61 елларда БАССРның Социаль тәэминат министрлыгында инспектор, 1961–66 да бүлек башлыгы. 1969–89 елларда Свердловск юридик ин-тында: 1984–87 дә халык хуҗалыгында хокук хезмәте ф-ты деканы. 1987 дән проректор. 1989–2002 дә Урал дәүләт хезмәте академиясенең социаль хокук каф. мөдире, 2002 дән Урал юридик академиясенең (Екатеринбург ш.) социаль хокук, дәүләт һәм муниципаль хезмәт каф. мөдире. Хезмәтләре социаль яклауның хокукый проблемаларына, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр хезмәтен көйләү мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Теория социального обеспечения: Юридический анализ. Саратов, 1982; Теоретические проблемы советского права социального обеспечения. Свердловск, 1986.

*Е.Б.Долгов.*

**ШӘЙХЕТДИ́НОВ** Зәйнулла Гайфулла улы (3.9.1936, БАССРның Бакалы р-ны Нарат Елга а. — 4.7.2001, Уфа ш.), очу аппаратлары двигательләре теориясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1973), проф. (1974), БАССРның, РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1976, 1992). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), шунда ук авиация двигательләре теориясе кафедрасында эшли. 1965 елдан Уфа авиация техникасы ун-тында, авиация двигательләре теориясе каф. мөдире (1969–90), авиация двигательләре ф-ты деканы (1983–88). Хезмәтләре очу аппаратларының двигательләрендә газ динамикасы һәм яну процессларына карый. Ш. яңа үрнәк авиация-ракета техникасы һәм энергетик җайланмалар төзү өчен теоретик база һәм гамәли тәкъдимнәр эшли. Очу аппаратлары двигательләрен җирдә файдалану эшләрен башлап җибәрә һәм оештыра. Уйлап табуга 85 авторлык таныклыгы бар. «Вопросы теории и расчёта рабочих процессов тепловых двигателей» вузара җыентыгының баш мөхәррире (1980 нән). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Состояние и перспективы разработки скважинных парогазогенераторов. М., 1983; Образование и выгорание сажи при сжигании углеводородных топлив. М., 1989; Технологические теплогазогенераторы. М., 1989.

**ШӘЙХЕТДИ́НОВ** Илсур Гәрәфи улы (2.1.1936, Биектау р-ны Мүлмә а.), нефть-газ үткәргечләр төзүче, Соц. Хезмәт Герое (1975). Арча пед. уч-щесен (1954), а.х.ын механикалаштыру уч-щесен (1955) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1955 елда Арча МТСында башлый. 1960–2010 да «Татнефтепроводстрой» АҖ тресты оешмаларында эшли: машинист-бульдозерчы, механикалаштырылган колонна башлыгы, өлкән прораб, линияле участоклар башлыгы (1969 дан), 1 нче комплекслы технол. идарә башлыгы (1983 тән), трестның ген. директоры урынбасары (1998 дән). 2000 нән АҖнең Каспий үткәргеч торбалар консорциумындагы вәкиле. 32 магистраль нефть-газ үткәргечләр, ш.и. Әлмәт-Горький, Миңлебай-Казан, Бохара-Урал, Идел буе-Үзәк төзелешендә катнаша. Көнбатыш Себердә үткәргеч торбалар сузганда Ш. җитәкчелегендәге бригада зур диаметрлы торбаларны 300 *м* лык аралыкларда эретеп ябыштыруның үрелмә ысулын кулланып, сазлык аша беренче поляр буе трассасын уздыра. Герой исеме Медьвежье (Төмән өлкәсе) — Үзәк газ үткәргече төзелешендә ирешкән зур уңышлары өчен бирелә. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале, КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС, ВЛКСМ ҮК Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Арча шәһәреннең Геройлар аллеясына бюсты куелган, Арча р-нының Түбән Аты авылында бер урам Ш. исеме б-н атала.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШӘЙХЕТДИ́НОВ** Наил Шәмсетдин улы (1.3.1941, Беренче Май р-ны Лашман а. — 25.1.2016, Казан), драма актёры, ТАССРның һәм РФнең халык артисты (1987, 2013). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1965), Татар драма һәм комедия театрында эшли. Аның тәүге рольләрендә үк — җаны әрнүдән үз эченә бикләнгән аз сүзле Әкбәр, тынгысыз Хәмзин («Кыр казлары артыннан», «Сандугачлар килгән безгә», И.Юзеев), күндәм, куркаграк Нариман («Үзебез сайлаган язмыш», Т.Миңнуллин), зирәк, хәйләкәр Насретдин («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт) кебек өл-

В.Г.Шәйхетдинов.
1. «Кече манара». 1996;
2. «Дин яралу». 1996;
3. Тарихчы, мәгърифәтче, илаһият галиме Ш.Мәрҗани портреты. 2012. «Казан» милли мәдәният үзәге.









Н.Ш. Ш ә й х е т д и н о в Хаҗи ролендә («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал).

кән яшьтәгеләр образларында актёр сәләтенең үзенчәлеге тулысынча ачыла. Ш. иҗат иткән геройлар тиз танып алына, әмма алар барысы да төрле холыклы һәм милли характерның төрледән-төрле чикләрен гәүдәләндерүче образлар галереясын тәшкил итә. Гайфи («Гайфи бабай, өйлән давай!», Г.Зәйнашева) ролендә аның образга керү сәләте аеруча ачык чагыла. Бу образ аша актёр геройның рухи



Н.Ш. Ш ә й х е т д и н о в Карт ролендә («Алтын көз», Ш.Фәрхетдинов).

ныклыгын, эчке сизгерлеген, рухи бәйсезлеген, какшамас тормышчан ныклыгын гаҗәеп оста гәүдәләндерә. Ш. ш.у. Баязит («Бөркетләр кыяга оялый», И.Юзеев), Габдрахман («Сәер кеше», Н.Хикмәт), Зыя («Башмагым», Т.Гыйззәт), Фәрит («Тол хатыннар көймәсе», И.Грекова) рольләрен дә зур уңыш б-н башкара.

*Әд.:* И л я л о в а И. Театр имени Тинчурина. К., 2002. *И.И.Илялова.*

**ШӘЙХЕТДИ́НОВ** Рәҗәп Юныс улы (7.4.1949, Уфа ш.), баянчы, педагог, проф. (1990), БАССРның һәм РСФСРның атказ. артисты (1976, 1985). 1972 елда Уфа сәнгать ин-тын (Ф.Беляков классы) тәмамлый. 1971 дән шунда ук укыта: 1983–91 дә һәм 1994 тән халык музыка уен кораллары каф. мөдире, проректор (1991–94). Бер үк вакытта, 1972 дән — Башкорт филармониясе, 1974 тән Росконцерт солисты. Ш. репертуарын көнбатыш Европа (И.С.Бах, Н.Паганини, Ф.Лист, И.Альбенис), рус (П.Чайковский), башкорт (А.Кукубаев, Н.Инякин, С.Низаметдинов һ.б.), татар (А.Ключарёв, Р.Курамшин), хәзерге композиторларның (Н.Чайкин, В.Золотарёв, Г.Шендерёв) әсәрләре тәшкил итә. Җыентыклар төзүче һәм аның нашире, баян өчен күчермәләр һәм эшкәртмәләр, методик кулланмалар авторы. Укучылары арасында халыкара һәм бөтенроссия конкурслары лауреатлары һәм дипломантлары — Д.Зиякаев, Д.Коновалов, О.Мельников, В.Лавришин, А.Искәндәров, Ф.Зәйнуллин. Мастер-класслар уздыра, концертлар б-н чыгыш ясый, Россия шәһәрләрендә һәм чит илләрдә (Германия, Финляндия, Польша,



Р.Ю. Шәйхетдинов.

Франция, Швейцария, Италия, Көньяк Корея, Словакия, Казакъстан, Литва һ.б.) уздырылган конкурсларда, ш.и. С.Сәйдәшев исем. 1 нче Халыкара халык музыка уен коралларында уйнаучылар һәм С.Сәйдәшев исем. халык музыка уен кораллары оркестрлары дирижёрлары конкурсында (Казан, 2010) жюри составында. Халыкара «Гармуннар көне» («Дни гармоники») конкурсы (Клингенталь ш., ГДР, 1972), музыка югары уку йортлары студентларының Бөтенроссия халык музыка уен коралларында уйнаучылар конкурсы (Новосибирск ш., 1969) лауреаты.

*Әд.:* Портреты баянистов. М., 1996.

**ШӘЙХЕТДИ́НОВ** Рәшит Рәхип улы (29.1.1957, Буа р-ны Норлат а.), инженер-төзүче, ТРның атказ. төзүчесе (1995), икътисад фән. канд. (2002), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). Ульянов техник ун-тын тәмамлый (1998). Хезмәт эшчәнлеген 1976 елда «Казанпромстрой» трестының 1нче төзелеш-монтажлау идарәсендә мастер буларак башлый. 1978–91 дә «Татавтодор»ның 3 нче юл-төзелеш идарәсендә: мастер, прораб, идарә башлыгы. 1990–91 дә 3 нче юл-төзелеш идарәсенең арендачылар оешмасы идарәсе рәисе; 1991–96 да һәм 2001 дән «Вираж» АҖдә (Буа ш.): идарә рәисе, ген. директор (1993–96, 2001 дән). 1996–2010 да «Татспиртпром» АҖ ген. директоры. 1999–2004 тә ТР халык депутаты. Дәүләт бүләге чүпрә генерациясенең анаэроб технологиясен эшләүдә һәм аны спирт җитештерүгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘЙХЕТДИ́НОВ** Роман Александрович (28.8.1974, Казан), хакимият эшлеклесе. Казан ун-тын тәмамлый (1996). 1995–97 елларда ТРның Тышкы икътисади элемтәләр министрлыгының хокук департаментында. 1997–98 дә ТР Финанс министрлыгының юридик бүлегендә. 1998–2000 дә «Телесет» АҖдә (Казан) бүлек мөдире, 2002–2006 да ген. директор. 2000–2002 дә «Телекоммуникация компанияләре челтәрләре» (Мәскәү) ген. директоры. 2006–11 дә «Телесет Нетворкс» компанияләр төркеменең баш операцион директоры һәм бер үк вакытта «Татарстан фәнни-җитештерү коммерция берләшмәсе» АҖ (Казан) ген. директоры. 2011–12 дә «Ростелеком» АҖнең ТРдагы ф-лы директоры. 2012 дән ТР Премьер-министры урынбасары — ТР мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘЙХЕТДИ́НОВ** Сабир Гафур улы (1.11.1936, Теләче р-ны Шәдке а.), галим агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999), ТАССРның атказ. агрономы (1983). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1946), «Большевик» к-зында баш агроном булып эшли (1999 дан — «Шәдке» кумәк пр-тиесе). Дәүләт бүләге туфракны чәчү алдыннан эшкәртү өчен блоклы-модульле культиваторлар җитештерүнең технол. нигезен булдыруда катнашканы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘЙХЕТДИ́НОВ** Фәрит Шәриф улы (5.6.1952, Чиләбе өлкәсенең Аша ш.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2004), проф. (2005). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), Чирмешән р-нының «Октябрьнең 50-еллыгы» к-зы рәисе урынбасары. 1980 елдан Казан аграр ун-тының үсемлекчелек кафедрасында. Хезмәтләре Урта Идел буе шартларында язгы йомшак бодай үстерү технологиясен камилләштерүгә карый.

Х е з м.: Интенсивные технологии производства яровой пшеницы // Система земледелия Татарской АССР. К., 1988 (автордаш); Производство продовольственного зерна яровой мягкой пшеницы в Республике Татарстан. К., 2001 (автордаш); Пути совершенствования технологии производства продовольственного зерна яровой пшеницы // Зерновое хозяйство. 2002. № 2 (автордаш).

**ШӘЙХЕТДИ́НОВА** Гөлнара Раиф кызы (4.12.1966, Казан), юрист, юридик фән. д-ры (2008). Казан ун-тын (1989), Чикаго шәһәрендәге (АКШ, 1994) Төньяк-Көнбатыш ун-тын тәмамлый. 1994–95 елларда ТР Президенты аппаратында. 1995–2001 дә ТР Дәүләт Советы рәисе киңәшчесе. 2001–09 да «ТИСБИ» идарә академиясенең конституцион һәм халыкара хокук кафедрасында. 2009 дан Казан ун-тының халыкара һәм Европа хокукы кафедрасында. Хезмәтләре халыкара, Европа хокукы, юрисдикцион иммунитет һәм дәүләтләр арасындагы хезмәттәшлеккә багышланган. Дәүләт һәм хокук теориясе муниципаль хокук буенча дәреслекләр авторы.

Х е з м.: Европейская социальная хартия. К., 2003; Европейская конвенция о защите прав человека и основных свобод и протоколы к ней. К., 2004; Продвинутое сотрудничество государств в европейском праве. К., 2007.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.



М.Ш. Шәйхиева.

**ШӘЙХЕТДИ́НОВА** Светлана Каим кызы (24.9.1957, Әзәрбайҗан ССР, Кази-Магомед ш.), журналистика өлкәсендәге галимә, журналист, филос. фән. д-ры (2004), проф. (2008). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1980), «Знамя коммунизма» г-тасында (Чаллы ш.), 1985–86 елларда «Комсомолец Татарии» г-тасында бүлек мөдире булып эшли. 1989 дан Казан ун-тында: журналистика каф. мөдире (2002 дән). Бер үк вакытта, 1996–97 дә, Хәбәрдарлыкны яклау фондының төбәк хәбәрчесе (Мәскәү), 1997–99 да Журналистлар хокукын яклау экспертлык үзәге (Казан) директоры, «Законодательство и практика средств массовой информации» (Мәскәү) бюллетененең Татарстан кушымтасы мөхәррире, 2006 дан Халыкара хокук һәм икътисад ин-тының авторлар хокукы буенча ЮНЕСКО каф. әгъзасы (Мәскәү), 2010 нан Казан төбәкара экспертизалар үзәге әгъзасы. Төбәк массакүләм мәгълүмат чараларында институциональ мөнәсәбәтләргә мониторинг, текстлар анализы методикалары эшли. Хезмәтләре техникалаштыру һәм технологияләштерү шартларында «кеше ситуациясе»нең фәлсәфи мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: «Четвёртая власть», по порядку номеров рассчитайсь!: Пресса Татарстана в середине 90-х годов. К., 1999; Экспертиза текстов массовой информации. К., 1999; Информационное общество и «ситуация человека»: Эволюция феномена отчуждения. К., 2004; Медиаэтика. К., 2007.

**ШӘЙХИ́ЕВА** Мәрфуга Шәйхи кызы (15.4.1920, Лаеш өязе, хәзер Питрәч р-ны Шәле а. — 12.5.2003, шунда ук), Соц. Хезмәт Герое (1975). 1936–78 елларда Питрәч р-ның Вахитов исем. к-зында эшли, сыер савучы (1951 дән). Алдынгы технологияне кулланып, районда беренчеләрдән булып һәр сыердан уртача 4000 *кг* нан артык сөт сава башлый. Герой исеме соц. ярышларда ирешкән зур уңышлары һәм 9 нчы бишьеллык (1971–75) йөкләмәләрен алдан үтәгәне өчен бирелә. Ике Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын, ике көмеш медальләре б-н бүләкләнә. Питрәч р-ының мактаулы гражданы. Районның төбәкне өйрәнү, Шәле тарих музейларында М.Ш.Шәйхиевага багышланган экспозицияләр куелган.

*Әд.:* М у л ю к о в М.А. Шәле таңнары: Тарихи очерк. К., 1977; Мишә буйлары — На берегах Мёши. К., 2006; А б у ш е в П.М., А б у ш е в М.П. Питрәч таңнары. К., 2008; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ШӘЙХЛИСЛА́МОВ** Зәйнулла Гомәр улы (2.1.1938, БАССРның Караидел р-ны Татар Өреше а.) нәкышьче, БРның атказ. рәссамы (1998). Уфа сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлый (1966), С.М.*Кәлимуллин* шәкерте. 1970–90 елларда Уфада Башкорт иҗат-җитештерү комб-тында рәссам. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1990). Станлы нәкышьнең лирик-романтик юнәлешендә танылган рәссам. Ш. картиналары төсләр байлыгы (салкын һәм җылы тоннарның үрелеп барышы), композициянең бизәклелеге б-н аерылып тора. Беренче эшләренең берсе булган «Сөембикә ханбикә» (1964) аның милли тамырларга карата кызыксынуын күрсәтә; рәссамның картиналарына хисләр тирәнлеге, нечкә ассоциацияләр хас. Камералы лирик пейзажларда татар авыллары күренешләрен («Иртә», 1974; «Макашевода яз», 1980; «Шарлыкта яз», 1982; «Кызыл төстәге ишегалды», 1984; «Авыл мәчете», 1987), Уфаның иске татар кварталларын, шәһәрнең хәзерге күренешләрен («Әңгер-меңгер», 1968; «Көмеш көн», 1970; «Мәчет», 1978, 1980; «Кояшлы көн», 1978; «Алсу төстәге өй», 1982; «Карагач», 1986; «Буран», 1988; «Урания», 1989; «Беренче кар», 1997) гәүдәләндерә; «Бөрҗән мотивлары» (1997–2005) пейзажлар сериясен булдыра. Ислам тарихына һәм традицияләренә мөрәҗәгать итә: «Согуд Гарәбстаны» (1984), «Пәйгамбәр улы», «Фәрештәнең тууы», «Мисыр» (барысы да — 1985), «Болгардагы Кара пулат» (1992), «Намазга» (1995), «Корбан бәйрәме» (1997), «Болгар. Борынгы төрбә», «Ерак үткәндә» (икесе дә — 1999), «Ата-баба җире» (2002). Натюрмортларда матур табигать дөньясын чагылдыра: «Натюрморт» (1975), «Хризантемалар» (1988), «Розалар» (1989), «Нәркәсләр» (1997), «Пионнар» (2000). Ш. ның графикасы нигездә портретларда гәүдәләнеш ала (күмер, карандаш): «Композитор Х.Заимов» (1968), «Кыз портреты», «Карт кеше портреты» (икесе дә — 1969), «Дуслар» (1978), «Пианистка» (1981) һ.б.

1976 дан респ-ка — «Җиделек альянсы» (Уфа, 1990), «Өч рәссам Татарстанда» (Казан, 1995; З.Г. һәм И.Г.Гаяновлар б-н бергә); бөтентатар — «Татарт» (С.-Петербург, Казан, 1991); төбәкара — «Социалистик Урал» (1979, 1991), «Урал-8» (1997), «Башкортстанның үз иреге белән Россиягә кушылуына 450 ел уңаеннан» (Мәскәү, 2007); халыкара — «Башкортстан Республикасы сәнгате Франциядә» (Париж, 2010) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1989, 2001, 2003, 2007 (Уфа), 2004 тә (Нефтекамск ш., Бәләбәй ш.) уздырыла. Әсәрләре Уфада М.В.Нестеров исем. Башкорстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм заманча «Урал» сәнгать галереясында, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Израильдә, Венгриядә, Төркиядә шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* В ә л и е в а - С ө л ә й м а н о в а Г. Җәйге ишек алды // Казан утлары. 1993. № 6; ш у л у к. Кояшлы тәрәзәләр // Тулпар. 1996. № 3; Зайнулла Шайхлисламов. Живопись. Графика: Каталог. Уфа, 1989; Ф е н и н а Э.П. Художники Башкортостана. Уфа, 2002; Е в с е е в а С. Тихая мелодия души Зайнуллы Шайхлисламова // Рампа. 2002. № 1.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ШӘКӘНӘ́Ч** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 3 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 119 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённая Шикенас, Шукенясь исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 496,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Әтнә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 64 ир-ат; 1859 да — 207, 1897 дә — 310, 1908 дә — 416, 1920 дә — 377, 1926 да — 371, 1938 дә — 374, 1949 да — 246, 1958 дә — 178, 1970 тә — 208, 1979 да — 174, 1989 да — 125, 2002 дә — 135 кеше.

**ШӘКЕ́РТ ДӘФТӘРЕ́**, элек мәдрәсә шәкертләре тарафыннан кулдан ясалып, зурлыгы ягыннан, башлыча, дәфтәр форматындагы яртысын тәшкил иткән, күләме 10–15 тән алып берничә йөз биткә кадәр булган «куен кенәгәсе». Эчтәлеге билгеле бер системага салынмаган, тематик яктан күптөрле: анда Коръән аятьләре, төрле характердагы догалар, гыйбрәтле риваятьләр, дини мөнәҗәтләр, халык авыз иҗаты үрнәкләре (бәетләр, җырлар, та-





З.Г.Ш ә й х л и с л а м о в. 1. «Иске Уфа». 1982; 2. «Иске мәчет». 1990.

бышмаклар, такмазалар һ.б.), шигърият өлгеләре, тарихи һәм төрле вакыйгалар (сугыш башлану, афәтле үлем, су басу, янгын чыгу, корылык, мул явым-төшем һ.б.) тасвирламасы, астрологик күзәтүләр (ай, кояш тотылу), дәрес биремнәре, хат язу үрнәкләре, тормыш-көнкүреш мәсьәләләре (сабанга чыгу, уракка төшү) һәм башкалар турында мәгълүмат теркәлгән.

Шигъри репертуарда билгеле татар, тугандаш казакъ, үзбәк һәм башка төрки халыкларның танылган шагыйрьләре әсәрләре б-н бергә классик фарсы әсәрләреннән дә өзекләр еш урын алган. Яшьләрнең аң-белемгә, мәгърифәткә омтылышларын чагылдырган махсус шәкерт җырлары, ягъни һәр строфа ахырында рефрен булып килгән «Тырышаек, без шәкертләр!» юллы садалар күп очрый.

Җәмгыятьтә иҗтимагый-сәяси вазгыятьнең үзгәреш кичерүе Ш.д. эчтәлегендә дә ачык чагылыш тапкан. XVIII йөздә бәетләр өстенлек итсә, XIX йөз ахырында — XX йөз башында, бигрәк тә 1905–07 елгы вакыйгалардан соңгы репертуарга башкача рухтагы әсәрләр килеп керә. Анда сүз мәдрәсәләрдәге уку-укыту системасын үзгәртергә кирәклеге турында бара.

Ш.д.ндә еш кына аның хуҗасының исеме, ул укыган мәдрәсә, остазлары турында белешмә урнаштырылган.

Ш.д. махсус тикшерүдән азат, чит-ятлар кулына керми торган хосусый кенәгә, хатирә язмасы буларак, хуҗасының гомерлек юлдашына әверелгән. Аларның кайберләре мәдрәсә биналарыннан чыгып, хуҗасы б-н бергә солдат казармаларында да булган, сугыш афәтләренә дә юлыккан, әсирлек михнәтләрен дә кичергән. Нәтиҗәдә, аңа мәгълүмат өстәлгән, эчтәлеге тулыланган.

Чыганак буларак, Ш.д. — зур әһәмияткә ия документ. Аның нигезендә әдәбият тарихын, фольклор хәзинәсен яңадан-яңа әсәрләр б-н баетырга, теге яки бу тарихи вакыйганы яктыртканда аңа ачыклык, төгәллек кертергә, татар мәгарифен өйрәнгәндә өстәмә материал булып хезмәт итәргә мөмкин.

*Әд.:* Г о с м а н о в М. Шәкерт дәфтәре - җырлар биштәре // Казан утлары. 1971. № 6; Г о с м а н о в М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. 1994.

*Р.Ф.Исламов.*

**ШӘКЕРТЛӘ́Р** (фарсы. — شاکرد), *мәдрәсә* укучылары. Уку йорты җитәкчесе карары б-н *мәктәпне* тәмамлагач кабул ителгәннәр. Мәдрәсәдә уку дәвамлылыгы билгеләнмәгән, укучының мөмкинлекләре һәм өлгерешенә бәйле рәвештә ул 10 елга һәм аннан да озаккарак сузылырга мөмкин була. 20 йөз башында иң озак уку вакыты 14 ел тәшкил итә. Кайбер мәдрәсәләрдә күп баскычлы укыту системасы хөкем сөрә. Мәс., Казанның *«Мөхәммәдия»* мәдрәсәсендә 3 разряд: башлангыч (5 сыйныф) — мәктәп курсын үз эченә ала, урта (6 сыйныф) — муллалар, мөгаллимнәр (мәктәпләр өчен укытучылар) һәм азанчылар (мәчет хезмәтчеләре), югары (3 сыйныф) — югары категориядә муллалар һәм мөдәррисләр (укытучылар) әзерли; Оренбургның *«Хөсәения»* мәдрәсәсендә 4 баскыч: башлангыч (3 сыйныф), урта (4 сыйныф), югарыга әзерлек (4 сыйныф), югары (3 сыйныф) баскычлар була. Дәресләр көн буе бара; кечкенә мәдрәсәләрдә төрле яшьтәге Ш., төркемнәргә бүленмичә, бер бүлмәдә укыйлар. Укыту өчен билгеләнгән түләү булмый, гадәттә, укытучыларга төрле төрдәге бүләкләр бирелә: чыганакларда күрсәтелгәнчә, укучылар һәм аларның ата-аналары, үзләренең хәлләренә һәм теләкләренә карап, җомга саен муллага һәм аның ярдәмчеләренә акчалата сәдака бирәләр; моннан тыш укучылар мөмкинлекләре буенча мәктәп бүлмәләрен җылыту һәм яктырту өчен акча бирәләр. 20 йөз башында кайбер мәдрәсәләрдә билгеләнгән түләү кертелә: «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уку өчен түләү 1913 тә һәр шәкерткә елга 10 сум була. Ш., гадәттә, мәдрәсәдә яшиләр. Мәдрәсәне муллалар үз акчаларына, вакуфтан кергән акчага (бу максатларда мәчетләргә сәдака итеп бирелгән күчемсез милек һәм капитал) тоталар. Күпчелегенең даими һәм тотрыклы табыш чыганагы булмый, шуңа күрә күп вакыт акчалары җитми. Ш. еш кына бик кысан шартларда укыйлар: биналар, гадәттә, кечкенә була (кайбер мәдрәсәләрнең генә җәмәгать биналары була, күп очракта алар мулла өендә урнашалар). Йокы бүлмәләре яисә мәктәп җиһазлары булмый, укучылар идәндә чыпталарда утыралар, йокы әйберләре шунда куела, гадәттә шунда ук ашыйлар да. Эчке тәртипкә күзәтчелек итү өчен мулла өлкән укучылар арасыннан карап торучыларны билгели, алар җыештыру һәм бинаны ягып җылыту эшләрен бүләләр. Иске ысуллы мәдрәсәдә Ш. ислам нигезен, гарәп графикасын, дини-схоластик фәннәрне, каллиграфия, арифметиканы өйрәнәләр. Программаның нигезен мөселман гыйлеме били, гомуми белем фәннәре ярдәмче характерда була. Яңа ысуллы мәдрәсәдә укыту программасына, дини фәннәрдән тыш, дөньяви фәннәр дә кертелә: гарәп, фарсы һәм рус телләре, география, тарих һ.б. Һәр мәдрәсә фәннәрне үз мөмкинлекләреннән чыгып сайлый, бердәм укыту программасы булмый; мәс., «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе Ш.е телләрне (татар, рус, гарәп, фарсы), әдәбият, арифметика, рәсем-сызым, физика, табигать белеме, география, тарих (гомуми, Россия, төрки халыклар тарихы, фән тарихы), филос., логика, психол., пед., юриспруденция, риторика, метрика, этика, мед., милекне бүлү турында фәнне («фараиз») өйрәнә. «Хөсәения» мәдрәсәсенең укыту планына 8 дини, 20 дөньяви фәннәр керә. Кайбер мәдрәсәләрдә рус мәктәпләренең барлык уку фәннәре укытыла. Мәдрәсәләрдә Ш. саны аерыла, бу мәдрәсә җитәкчеләре — мөдәррисләр һәм муллаларның укымышлылык дәрәҗәсенә һәм популярлыгына бәйле була. «Мөхәммәдия» кебек зур мәдрәсәләрдә 20 йөз башында 500 дән артык укучы, 20 мөгаллим исәпләнә, һәм кечкенә, мәс., Казандагы 5 нче таш мәчет каршындагы Сәгыйть мәдрәсәсендә барлыгы 42 укучы укый. Казан губернасында 25 мәдрәсә эшли, аларда 1944 ир һәм 90 кыз балалар укый. Ш. у. Казанда «Касыймия», Уфада «Галия» һәм «Госмания», Оренбургта «Хөсәения», Троицкида «Рәсүлия» мәдрәсәләре киң танылу алалар. Зур яңа ысуллы мәдрәсәләрдә чагыштырмача фикер хөрлеге хөкем сөрә, кайбер Ш. формаль булмаган җәмгыятьләргә берләшәләр, кульязма журналлар, газеталар чыгаралар, спектакльләр куялар. Революцион чуалышлар шартларында 20 йөз башында болар барлык дини укыту системасына радикаль реформа уздыруны максат итеп куйган көчле *Шәкертләр хәрәкәте* барлыкка килүгә этәрә.

Чыг.: Медресе г. Казани XIX — нач. XX вв.: Сб. док. и материалов. К., 2007; Медресе Казанской губернии второй трети XIX — начала XX в.: Сб. док. и материалов. К., 2012.

*Л.М.Айнетдинова.*

**«ШӘКЕРТЛӘ́Р ТАҢЫ́»**, айлык рәсемле журнал. Ерак Шәрекъ төрки-татар мөселманнарының дини-милли «Идел-Урал» мәркәзе органы. 1934–35, 1939–40 елларда Мукден шәһәрендә (хәзер Шэньян, Кытай) татар телендә нәшер ителә. Журналның максаты — Мукден шәһәрендәге үсеп килүче буынны, ш.и. шәкертләрне милли рухта тәрбияләү.Татар диаспорасының мәдәни, дини тормышын, аерым алганда, мәгариф, дини йолаларны үтәү, финанс проблемаларын хәл итү б-н бәйле мәсьәләләрне яктырта.

**ШӘКЕРТЛӘ́Р ХӘРӘКӘТЕ́**, 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Россиядә татар яшьләренең иҗтимагый-сәяси хәрәкәте. Максатлары — мәдрәсәдә укыту системасын үзгәртеп кору, мәктәптә белем бирүне демократияләштерү һәм европалаштыру, татарлар арасында милли-азатлык хәрәкәте идеяләрен пропагандалау һ.б. Казанда җитәкчеләре И.Гаспралының белем бирү һәм сәяси программасын яклаган Казан татар укытучылар мәктәбе, яңа ысуллы «Мөхәммәдия» һәм Апанаев мәдрәсәләре Ш.х. үзәкләре булып китә. Ш.х. лидерлары: Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, С.Максуди, Ә.Максуди, Ф.Туктаров, И.Әмирханов, И.Бикколов, Г.Терегулов, К.Мотыйгый, М.Укмаси, Г.Тукай, М.Гафури





1. Шәкертләр. 20 йөз башы фоторәсеме; 2. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре. 20 йөз башы.



Ә.Х.Шәкүров.

һ.б. Укучыларның беренче яшерен оешмасы 19 йөз ахырында Казанда Казан татар укытучылар мәктәбе инициативасы б-н барлыкка килә, 1901 елда әлеге оешма «*Шәкертлек*» исемен ала, аның эшчәнлегенә Идел буе, Урал яны, Себер һәм Кырымның укучы яшьләре тартыла. 1904 тә аның базасында «Хөррият» сәяси оешмасы төзелә. 20 йөз башында Ш.х. гомумроссия революцион хәрәкәте йогынтысында активлаша, татар яшьләренең «*Иттихад*», «*әл-Ислах*», «*Берек*», «*Таңчылар*», «*Җәмгыяте гыйльмия*», «*Гыйльми мәҗлес*» иҗтимагый-сәяси оешмалары барлыкка килә. Ш.х.ндә катнашучылар укучы татар яшьләре арасында аңлату эше алып баралар, легаль булмаган газеталар һәм журналлар (башлыча кульязма хәлендә): «әл-Гасрелҗәдит», «әл-Ислах», «әл-Мәгариф», «Тәрәккъый» һ.б. чыгаралар, әдәби кичәләр, татар музыкасы концертлары оештыралар, пьесалар һәм спектакльләр куялар. «әл-Ислах» Идел буе һәм Урал яны шәкертләренең иң массачыл оешмасы булып санала, Казанда аның ҮКы, Уфада, Оренбургта, Троицкида һ.б. шәһәрләрдә бүлекләре була. «әл-Ислах» башлангычында Казанда татар шәкертләренең легаль булмаган ике Бөтенроссия съезды (1906 елның 10–15 мае, 1907 нең 10 мае) булып уза, аларның эшендә Оренбург, Троицк, Уфа, Буа, Иж-Бубый һ.б. мәдрәсә шәкертләре вәкилләре катнаша. Соңгы корылтайда татар мәгарифен үзгәртеп коруга юнәлтелгән программа кабул ителә: башлангыч мәктәпне яңа ысуллы милли мәктәп итеп үзгәртү; бер шәһәрдәге мәдрәсәләрне бер уку йортына берләштерү; мәдрәсәнең бер өлеше урта (игъдадия), ә икенче өлеше югары (галия) белем бирү баскычы булырга тиеш; укыту методикасын тәртипкә салу; гыйльми фәннәр, рус һәм гарәп телләрен укытуны эченә алган бердәм укыту программасын булдыру; укыту программасы төзү һәм мәдрәсәләр эшчәнлеген контрольдә тоту өчен автономияле белем бирү органы (коллегия) оештыру; мәдрәсәләр б-н эчке идарәне шәкертләр һәм укытучылар вәкилләреннән торган коллегия кулына тапшыру. «Берек» яшерен оешмасы программасы мәдәни-агарту максатыннан тыш (ирләрне һәм хатын-кызларны гомуми укытуны гамәлгә ашыру, укытуны фәкать татар телендә генә алып бару, урта һәм югары мәктәпләрдә рус телен укыту предметы буларак өйрәнү, рухани һәм дөньяви белем бирүдә автономияле система кертү, мәхәллә муллаларын һәм байларын мәдрәсәләр б-н җитәкчелек итүдән читләштерү, финанслау мәсьәләсендә рус һәм татар мәктәпләренең тигезлеген тану) радикаль сәяси таләпләрне (самодержавиене бәреп төшерү, Россиядә конституцион строй кертү) колачлаган бердәнбер шәкертләр оешмасы була. 1905–07 елгы Рев-ция чорында шәкертләр сәяси митинглар һәм демонстрацияләрдә актив катнашалар, 1906 ның 27 февралендә Казанда шәкертләрнең 1,5 мең кешелек гомуми забастовкасы була. Рев-циядән соң Ш.х. кими төшә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе җитәкчесе Г.Баруди Казаннан сөрелә, радикал юнәлештәге күп кенә шәкертләр мәдрәсәдән куыла. Ш.х. үзәге бертуган Бубыйлар мәдрәсәсенә (Вятка губ. Сарапул өязе Иж-Бубый а.) күчә; 1911 дә ул ябыла. Ш.х.нә катнашучыларның күбесе татар радикал-демократик юнәлеш вәкилләре б-н тыгыз бәйләнештә була һәм алга таба төрки-татар сәяси оешмаларын формалаштыруда әйдәп баручы ролен үти.

*Әд.:* Н у р у т д и н о в И.Г. Молодёжь в тюрко-татарском идейно-политическом движении начала XX века: Дис. ... К., 2000; Ф а х р у т д и н о в Р.Р. Политическое самосознание татар на рубеже веков (вторая половина XIX — начало XX вв.).К., 2006.

*Л.М.Айнетдинова.*

**«ШӘКЕРТЛЕ́К»**, Казанда 1901– 04 елларда татар яшьләренең яшерен оешмасы. Бер төркем Казан татар укытучылар мәктәбе укучылары тарафыннан төзелә; актив әгъзалары арасында — Г.Г.Исхакый, Г.Й.Колахмәтов, С.Н.Максуди, Ә.Н.Максуди, Ш.З.Мөхәммәдъяров, Г.Х.Терегулов, Ф.Ф.Туктаров. Оешманың программасы хөкүмәткә каршы юнәлтелгән була. «Ш.» татарларны милли бәйсезлек өчен көрәшкә чакыра. «Тәрәккъый» («Прогресс») кульязма г-тасын чыгара. Идел буе, Урал яны, Себер, Кырымда яшәүче төрки-татарларның иҗтимагый-сәяси аңын формалаштыруга зур йогынты ясый. «Хөррият» сәяси оешмасы итеп үзгәртелә.

*Әд.:* Ф а х р у т д и н о в Р.Р. Политическое самосознание татар на рубеже веков (вторая половина XIX — начало XX века). К., 2006.

**ШӘКУ́ЛОВА** (Шакулова) Сара Касыймхан кызы (27.7. 1887, Рязань губ. Касыйм ш. — 1964, Мәскәү), педагог. «Физик культура» белгечлеге буенча П.Ф.Лесгафт курсларын (С.-Петербург), 1913 елда Париж ун-тының (Сорбонна) физика-матем. бүлеген тәмамлый. 1915 тән Рязань губернасы Зарайск шәһәре реаль уч-щесендә, 1916 дан Казан уку йортларында — коммерция уч-щесендә, Ф.Аитова гимназиясендә, Л.Хөсәения мәктәбендә укыта. 1919 дан БАССР мәгариф халык комиссары урынбасары, һөнәри уку йортларын оештыру б-н шөгыльләнә. 1923–37 дә РСФСР Мәгариф халык комис-тының милли мәктәпләр бүлеге инспекторы, бер үк вакытта, 1925–37 дә, Мәскәүдә татар урта мәктәбе директоры. 1938–63 тә Мәскәү техник югары уку йортларында укыта.

*Әд.:* Б и к т и м и р о в а Т.А. Ступени образования до Сорбонны. К., 2003; М а х м у т о в а А.Х. Пора и нам зажечь зарю свободы! (Джадидизм и женское движение). К., 2006.

**ШӘКУ́Р бине́ ГАВА́З** (Әмдәми), (17 йөзнең 2 нче яртысы — 18 йөзнең 1 нче яртысы), суфи шагыйрь. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң (1694), Тубыл шәһәрендә ахун булып хезмәт итә. Дини-дидактик әчтәлекле «Нәсыйхәтнамә» (Тубыл, 1703) поэмасы авторы. Китап суфичылык идеяләре нигезендә һәм фарсы шагыйре Ф.*Гаттарның* «Пандна-мә» әсәре тәэсирендә иҗат ителә. Моны поэмада Ш.б.Г. үзе дәлилли. «Нәсыйхәтнамә»дә автор кеше тәрбияләү һәм кешенең үз-үзен тәрбияләү проблемасын күтәрә. Кешене байлыкка омтылмаска, гөнаһ кылмаска, өметен өзмәскә, авырлыкларны һәм сынауларны сабырлык б-н кичерергә өнди, чөнки, аның фикеренчә, дөньяда барлык нәрсә Аллаһ кушканча була.

*Әд.:* С а й ф у л и н а Ф.С. Произведение Амдами «Насихатнамэ» в контексте суфийской литературы средневековья // Вестн. Башк. ун-та. 2010. Т. 15, № 1. *А.М.Ахунов.*

**ШӘКУ́РОВ** Әнәс Харис улы (31.8.1941, Әлмәт р-ны Бигәш а. — 1.12.1989, Әлмәт ш.), слесарь-монтажчы, Хезмәт Даны орденының тулы кавалеры (1974, 1978, 1983). Хезмәт эшчәнлеген туган авылы колхозында башлый. 1959–62 елларда Әлмәт р-нының элемтә бүлегендә монтёр. 1962–89 да «Востокмонтажгаз» трестының 5 нче махсуслаштырылган идарәсендә (Әлмәт): слесарь-монтажчы, газ б-н кисүче, бригадир (1970 тән). Ш. җитәкләгән бригада әһәмиятле объектлар — Миңлебай газ эшкәртү з-ды, Оренбург газ комплексы, Оренбург–Казан, Миңлебай–Казан этан үткәргечләре, Самотлор–Усть-Балык–Әлмәт нефть үткәргече, Әлмәт шәһәренә кадәр Кама суүткәргече төзелешләрендә актив катнаша. Монтажлау эшләрендә алдынгы технологияләрне куллану ел саен җитештерүдәге йөкләмәләрне 130–150 % ка үтәргә, шактый акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирә. Коллектив трест бригадалары арасында беренчеләрдән булып понтонлы резервуарларны монтажлау ысулын үзләштерә. Фидакарь югары җитештерүчән хезмәте, Бөтенсоюз соц. ярышларда ирешкән зур уңышлары, бер пр-тиедә күп еллар эшләгәне өчен орденнарга лаек була. Медальләр б-н бүләкләнә. Әлмәт шәһәрендә Геройлар аллеясында Ш. бюсты куелган.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003. *Г.Я.Мәүлетова.*

**ШӘКУ́РОВ** Вакыйф Закир улы (3.1.1904, Казан губ., Спас өязе Чуаш Кичүе а. — 16.3.1973, Казан), галим агроном, селекция белгече, ТАССР, РСФСРның атказ. агрономы (1963, 1968). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1932), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында кузаклы культуралар төркеме мөдире. Борчакны тиз үрчетү технологиясен эшли. Борчакның берничә сорты, ш.и. «Казан 38» сорты (1960–70 елларда респ-када 60 мең *га* дан артык чәчелә) авторы. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘКУ́РОВ** Илдар Гомәр улы (28.4.1956, Куйбышев өлкәсенең Кошки р-ны Тёплый Стан а.), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (2003), проф. (2004), РФнең атказ. табибе (1999). Куйбышев мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), шунда ук эшли. 1981 елдан 1 нче тире-венерология диспансеры мөдире (Куйбышев ш.), 1986 дан Самара өлкә тире-венерология диспансеры баш табибе,

1997 дән Самара мед. ин-тында. Хезмәтләре мед.-социаль мәсьәләләрне, җенси юл б-н күчә торган авыруларны өйрәнүгә карый. Самара өлкәсе Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш белгеч-дерматовенерологы (1986 дан). Уйлап табуга 4 патенты бар.

Х е з м.: Принципы терапии кожных болезней и инфекций, передающихся половым путём. Самара, 2002 (автордаш); Профилактика профессиональных заболеваний кожи. Самара, 2002 (автордаш); Диагностика инфицирования микробактериями туберкулёза детей с атопическим дерматитом. Самара, 2012 (автордаш).

**ШӘКҮ́РОВ** Ильяс Гомәр улы (20.2.1965, хәзер Самара өлкәсенең Елховка р-ны Тёплый Стан а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2010). Куйбышев ун-тын тәмамлый (1990). 1990–97 елларда Самара шәһәренең төрле оешмаларында эшли. 1997–2000 дә «Самара коммерция фермер банкы» ҖЧҖ идарәсе рәисе. 2000–09 да «Самара ипотека — җир банкы» ҖЧҖнең президенты, бер үк вакытта, 2006 дан, Идел буе соц.-гуманитар академиясендә, икътисад фән. каф. профессоры (2011 дән). Фәнни эшләре хезмәт күрсәтү өлкәсендә базар һәм дәүләт көйләү системаларының үзара мөнәсәбәте, Россиянең глобаль финанс хезмәте базарына интеграциясе мәсьәләләренә карый. Киң җәмәгать эшчәнлеге алып бара: «Самара өлкәсенең татар эшмәкәрләренә ярдәм ассоциациясе» милли-мәдәни җәмгыяте президенты (2012 дән).

Х е з м.: Государственное регулирование комплекса финансовых услуг. СПб., 2007; Новая эпоха и проблемы трансформации российской экономики // Материалы науч.-практ. конф. «Актуальные проблемы менеджмента в России на современном этапе: проблемы внедрения управленческих инноваций в мезо-экономических системах». СПб., 2008; Исламские банки: сегодня и завтра // Актуальные вопросы современной науки. Новосиб., 2009. Вып. 6, кн. 2.

**ШӘКҮ́РОВ** Мөхәммәтфатих Шәкүр улы (1.4.1931, Ворошилов р-ны Яңа Абдул а.), вет. хирургы, вет. фән. д-ры (1984), проф. (1985), ТРның, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1991, 1998), РФнең атказ. югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2001). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Сарман районара вет. лаб-ясе мөдире булып эшли. 1963–2010 елларда Казан вет. медицинасы академиясендә, гомуми һәм аерым хирургия каф. мөдире (1984 тән). Хезмәтләре хайваннарда үпкә авыруларын патогенетик дәвалау ысулларына, хайваннарның хирургик патологияләрен дәвалау мәсьәләләренә карый. Күкрәкнең эчке нервларына новокаин блокадасы ясауның яңа ысулларын эшләп гамәлгә кертә. Уйлап табуга 2 патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999).

Х е з м.: Новокаиновые блокады в ветеринарии. М., 2007 (автордаш); Топографическая анатомия домашних животных. М., 2008 (автордаш); Основы общей ветеринарной хирургии. СПб.–М.–Краснодар, 2011.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

**ШӘКҮ́РОВ** Рафаил Хәйрулла улы (13.2. 1930, Чуаш АССРның Батыр р-ны Озын Кулак а.), психолог, психол. фән. д-ры (1979), СССР ПФА (1989; 1993 тән РМА), Чуаш Респ-касы ФА академигы (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1953), Новосибирск өлкәсенең Чулым тимер юл станциясендә мәктәп директоры булып эшли. 1963 елдан Украина ССР Мәгариф министрлыгының Психол. ин-тында (Киев). 1976 дан Казанда: ПФАнең Һөнәри-техник пед. ин-тында (хәзер Һөнәри белем бирүнең пед. һәм психол. проблемалары ин-ты), директор урынбасары (1979 га кадәр), 1976–95 тә идарә итү психологиясе лаб-ясе мөдире, проф.(1984). 1996–2006 да РМАнең Идел буе бүлеге рәисе. Бер үк вакытта, 1997 дән, Казан технол. ун-тының социаль эшләр, пед. һәм психол. кафедрасында. Хезмәтләре шәхеснең формалашуы, шәхесара мөнәсәбәтләр , пед. коллективлар б-н идарә итү психологиясе мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Самолюбие детей: Дошкольный возраст. М., 1969; Человек формируется с детства. М., 1972; Социально-психологические проблемы руководства педагогическим коллективом. М., 1982; Социально-психологические основы управления: Руководитель и педагогический коллектив. М., 1990; Рождение личности: новая парадигма. К., 2007.

**ШӘКҮ́РОВ** Сәет Габделхәй улы (14.12.1917, Казан губ., Лаеш өязе Балыклы Чүкәй а. — 12.9.1989, Казан), драматург, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1970). Татар сәнгать техникумын тәмамлаганнан соң (1938), Минзәлә, Мамадыш, Әлмәт колхоз-совхоз театрларында эшли (1938–42, 1946–56). 1956 елдан Татар акад. театрында актёр, 1959 дан баш администратор, 1975–79 да Татар драма һәм комедия театры директоры. Ш.ның «Орденлы Касыйм» исемле беренче пьесасы 1938 дә нәшер ителә. Гаиләдәге тәрбия мәсьәләләренә багышланган «Тормыш бусагасында» пьесасы (1938, Минзәлә татар драма театрында куела, 1958) драматургка уңыш китерә. Шигырь формасында язылган «Зөһрә йолдыз» трагедиясе, «Уракчы кыз», «Мәхәббәт газабы» драмалары, «Кыз бирү», «Карт гашыйк» комедияләре 1960 елларда Минзәлә һәм Оренбург татар театрлары сәхнәләрендә куела. «Туган туфрак» (Татар акад. театрында куела, 1969) һәм «Тол хатыннар, тол кызлар» (Татар акад. театрында куела, 1973) пьесалары Бөек Ватан сугышы чорында совет халкының батырлыгына багышлана. «Артист» повестенда (1989) күчмә театр артисты язмышы күрсәтелгән. Ш. әсәрләренә романтизм, геройларны тасвирлауда психол. тирәнлек хас. Бөек Ватан, совет-япон сугышларында катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сине ташлап китә алмыйм: пьесалар. К., 1983; Пьесалар. К., 1987.

*Әд.:* М ә х м ү т о в Һ. Сәет Шәкүровның драмалары // Казан утлары. 1971. № 2.

**ШӘКҮ́РОВ** Яков Савельевич (Якуб Сәлах улы) (30.7.1912, Түбән Новгород ш. — 19.7.1944, Латвия ССР, Лудза ш. паркында җирләнә), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, үлгәннән соң), рядовой. Омск шәһәрендә заводта эшли. 1941 елның июненнән Кызыл Армиядә һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында, 375 нче укчы полк укчысы (3 нче удар армиянең 219 нчы укчы дивизиясе). 1 нче һәм 2 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Невель һөҗүм операциясендә (1943), Идрица юнәлешендәге сугышларда (1944), 1944 нең 19 маенда Латвия ССР терр-ясендә дошманның оборона линиясен өзүдә катнаша: Схороновая авылы тирәсендә солдатлар взводы составында дошман траншеясына бәреп керә; дошманның 50 гә якын солдаты юк ителә, 18 е әсирлеккә алына. 1944 нең 19 июлендә Рундены посёлогы янында (Латвия ССРның Лудза р-ны) барган сугышта батырлык күрсәтә: 10 разведчиктан торган төркем, камалышта сугышып, ике тәүлек буе тактик яктан әһәмиятле биеклекне өстәмә көчләр килеп җиткәнче саклап тора, төркем дошманның 200 солдатын юк итә, Ш. шушы сугышта һәлак була. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә. Рунденың пос. янында геройларның исемнәре язылган обелиск, Лудза шәһәрендә һәйкәл куела. Омск шәһәрендәге бер урам Ш. исемен йөртә. Ул эшләгән завод цехы бинасына мемориаль такта куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.
*М.З.Хәбибуллин.*



Я.С. Шәкүров.



Һ.З. Шәкүрова.

**ШӘКҮ́РОВА** Һаҗәр Закир кызы (24.6.1940, Саба р-ны Байлар Сабасы а. – 26.6.2019, Казан), драма актрисасы, ТССРның халык артисты (1991). Сәхнә эшчәнлеген 1963 елда Казан курчак театрында башлап җибәрә, 1964 тән Татар респ-ка күчмә театрында (хәзер Татар драма һәм комедия театры), аның сәхнәсендә шактый гына зур образлар тудыра. Труппаның әйдәп баручы актрисаларыннан берсе. Айгөл («Айгөл иле», М.Кәрим)



Һ.З. Ш ә к ү р о в а Айгөл ролендә («Айгөл иле», М.Кәрим).



Һ.З. Ш ә к ү р о в а Лиза ролендә («Сары чәчәк ата көнбагыш», А.Гыйләҗев; сулда Анна ролендә – И.И.Мәхмүтова).

ролендә романтизм билгеләре, тормышны ярату хисе көчле чагылыш таба. Лиза («Сары чәчәк ата көнбагыш...», А.Гыйләҗев) ролендә Ш. кабахәтлек һәм икейөзлелеккә юлыккан әхлакый саф кешенең күңел төшенкелеген тирән драматизм һәм көчле хис-кичерешләр б-н гәүдәләндерә, Ленинград блокадасын кичергән Флүрәнең («Тол хатыннар көймәсе», И.Грекова повесте буенча) бай рухи дөньясын ышандырырлык итеп ача. Актриса ш.у. Мөршидә («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Җиһан («Аршин мал алан», У.Хаҗибәков), Жаннина («Кызыклы хәл», К.Гольдони), Ләлә («Гашыйклар тавы», И.Юзеев), Әлфия («Умырзая», В.Сәйфуллин), Тамара («Шамакай», В.С.Розов) рольләрен жанр табигатен нечкә тоеп башкара.

*Әд.:* И л я л о в а И. Театр имени Тинчурина. К., 2002. *И.И.Илялова.*

**ШӘЛЕ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 10 *км* көньяктарак, Казан — Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 2838 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Казан күн берләшмәсе цехы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, амбулатория. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.дә 2 мәчет (берсе генә сакланган, 1895 тә төзелә; архит-ра истәлеге), 2 мәдрәсә, ашлык саклау-сату кибете, 1 җил һәм 2 су тегермәне, тимерче алачыгы, кредит ширкәте, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4344 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Сәләнгеш волостенда, 1920 дән ТАССР-ның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 186 ир-ат; 1859 да — 1308, 1897 дә — 2217, 1908 дә — 2562, 1920 дә — 2845, 1926 да — 2538, 1949 да — 2433, 1958 дә — 2872, 1970 тә — 3455, 1979 да — 3302, 1989 да — 3131, 2002 дә — 2953 кеше. Ш.дә Россия мөфтиләре шурасы рәисе Р.*Гайнетдин* туган.



Шәле авылы мәчете. 1895.

**ШӘМ КҮЛЕ́**, Идел алдында. Коры Үләмә һәм Карамалы елгаларының субүләрендә, Кама Тамагы р-ны Чаллы авылыннан 0,6 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. Су өслегенең мәйданы 5,44 *га*. Су күләме 50 мең $м^3$. Озынлыгы 760 *м*, иң зур киңлеге 140 *м*.



Шәм күле.

Уртача тирәнлеге якынча 1 *м*, иң зур тирәнлеге 3 *м* тирәсе. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы катлаулы. Көньяк яры күтәренке һәм текәрәк. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, җиңелчә минеральләшкән, төсен үзгәртүчән. Үтә күренмәлелеге 40 *см*. Сугару өчен файдаланыла. Ял итү урыны.

**ШӘМ-СТЕАРИ́Н, САБЫ́Н КАЙНАТУ́, ГЛИЦЕРИ́Н ХИ́МИЯ ЗАВОДЫ́**, б е р т у г а н К р е с т о в н и к о в л а р н ы ң ф а б р и к а - с ә ү д ә ш и р к ә т е н е к е. 1885 елда Мәскәү эшмәкәрләре *Крестовниковлар* тарафыннан нигезләнә. Шәһәрнең көньяк өлешендә Бирге Кабан күленең көнбатыш ярында урнашкан. Башта завод корпусы — озынлыгы 48 сажин, киңлеге 19 сажин булган бер катлы таш бина төзелә. 1871 гә завод 22 дисәтинәдән күбрәк мәйдан били, анда 100 дән артык корылма, ш.и. 5 фабрика корпусы урын ала (1919 га мәйданы 28 дисәтинәдән арта). Пр-тие каршында газ з-ды, мичкәләр ясау, механика, пар казаннары һәм такта яру остаханәләре, лаб. була. 1857 дә эшчеләр саны — 200 кеше, 1913–14 тә 2200 кеше тәшкил итә. 1856–57 дә пр-тие 80 мең пот чамасы продукция, 1913 — 14 тә 639 мең пот шәм, 498 мең пот сабын, 311 мең пот олеин к-тасы, 133 мең пот глицерин һ.б. эшләп чыгара. Россиядә шәм җитештерүдә завод өлеше — 42% тирәсе, сабын җитештерүдә 8,4% тәшкил итә (1908). Продукция Россия төбәкләренә, аның бер өлеше Англиягә, Франциягә һ.б. илләргә җибәрелә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында пр-тие каршында аспирин, чистартылган карбол һәм салицил к-талары һ.б. чыгарылган фенол-салицил з-ды оештырыла. Завод продукциясе Россиядәге һәм халыкара күргәзмәләрдә күрсәтелә. Пр-тие Лондон бөтендөнья күргәзмәсенең мактаулы бәяләмәсенә (1862), Париж бөтендөнья күргәзмәсенең көмеш (1867) һәм алтын (1878, 1889) медальләренә, Мәскәүдәге Бөтенроссия күргәзмәсенең иң югары бүләгенә (1882) лаек була. Крестовниковлар з-ды б-н галим-химиклар А.М., К.М., М.М., П.М.Зайцевларның, А.Е.Арбузовның һ.б. эшчәнлеге бәйле. 1919 да завод национализацияләнә. 1922 дән — «Мулланур Вахитов исемендәге дәүләт сабын кайнату, шәм һәм химия заводы» (хәзер «*Нәфис Косметикс*») АҖ. Ш.у.к. *Крестовниковлар заводы биналары комплексы*.

*Әд.:* Стеариновый-химический и мыловаренный заводы фабрично-торгового товарищества братьев Крестовниковых в России (Казань): Некоторые сведения для всемирной выставки в Париже 1900 г. К., 1900; К л ю ч е в и ч А.С. История Казанского жирового комбината имени Мулла-Нур Вахитова (1855–1945). К., 1950; История Казани. К., 1988. Кн. 1. *И.Р.Вәлиуллин.*

**ШӘМАЙ́Л** (гарәп. شمايل — сыйфат, дәрәҗә), каллиграфия ысулында Коръән текстлары язылган, күренешләр (изге урыннар, мәчетләр һ.б.) һәм сюжетлы символлар төшерелгән дивар панносы. Пыялада (классик Ш.), кәгазьдә (ш.и. ташбасма ысулы б-н), тукымада (чигү, укалап чигү, к. *Ләүхә*) эшләнә, аннары кысаларга урнаштырып өй һәм мәчет интерьерларына куела. Гарәп мәдәниятендә пыялага рәсем төшерү халык эпосы каһарманнары сурәтләнгән халыкчан гади картина рәвешендә яши. Татар Ш.ендә кеше сурәте, кагыйдә буларак, ясалмый.

Беренче Ш.ләр 19 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килә. Алар пыяланың икенче ягына майлы буяу б-н ясала, алтын һәм көмеш фольга фонында агач яки камыш кысага урнаштырыла. Нигездә, Казанда һәм Казан арты авылларында яшәүче татарлар арасында таралыш ала. Кама аръягы һәм Урал буе, ш.у. Көнбатыш Себердә Ш. каты кәгазьгә кара һәм төсле тушь, акварель б-н ясала.

Татар мәдәниятендә Ш. изге предмет булып исәпләнелә һәм иң мәртәбәле урынга — өйнең интерьерына, еш кына ишек өстенә яки ишеккә каршы ягтагы диварга куела. Ш. табыну объекты түгел, ул мөселман татарларның Коръән өйрәтмәләренә ихтирамын, ислам дине кыйммәтләренә бәйләнешен чагылдыра.

Төрле композицион типлардагы Ш.дә гарәп язмасының төрле каллиграфик ысулларда башкарылган язулары архит-ра һәм пейзаж күренешләре, чәчәк-үсемлек орнаментлары, дини символлар, предметлар, парлы кошлар һ.б. сурәтләр б-н тулыландырыла. Андый төрлелек Ш.не каллиграфия, сүз, нәкышь, графика сәнгатен берләштерә торган иҗатның синтетик төре итеп карарга мөмкинлек бирә. Ш.дә дини текст б-н бергә еш кына фәлсәфи тәгъбирләр, Шәрекъ һәм татар авторлары — Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Г.Тукай, Дәрдемәнд әсәрләреннән юллар, мәкаль-әйтемнәр, нәсыйхәт текстлары, гыйбрәтле сүзләр дә языла.















**Шәмаил.** 1. Билгесез автор. Кара фонда манаралар белән «әл-Көрси» аяте язылган шәмаил. Пыяла. Майлы буяу, ука. 20 йөз башы; 2. Я.Мотаһир. «Кешенең сәламәтлеге - телне саклый белүдә». Пыяла. Майлы буяу, ука. 20 йөз башы; 3. Г.Сәлиев. «Аллаһ - саклаучыбыз һәм шәфкатьледән шәфкатьлесе». Пыяла. Майлы буяу, ука. 20 йөз башы; 4. Билгесез автор. «Мөхәммәд пәйгамбәр һәм Гали хәлифә». Кәгазь. Басма. «Кәримовлар басмаханәсе, ташбасмасы һәм хәреф кою ширкәте». Казан. 1911. Ш.Мәрҗани фонды; 5. Мөхәммәтҗан Хәлил угылы Хуҗасәет. «Икенче сәфинәи Нух». Төсле ташбасма. 1904. ТР Милли музее; 6. А.Абдуллин. «Кәгъбә». Кәгазь. Басма. В.Еремеев һәм А.Шашабрин басмаханәсе. Казан. 20 йөз башы. ТР Милли музее; 7. Билгесез автор. «Һәм бел, Ля илаһе иллаллаһ Мөхәммәд рәсулуллаһ». «Хөсәенов варислары» басмаханәсе. Казан. 1910. Кәгазь. Басма; 8. Билгесез автор. «Кем гыйлемгә омтыла, аңа җәннәт омтыла». Хәдис. Ташбасма. В.В.Вараксин ташбасмаханәсе. Казан. 20 йөз башы. Ш.Мәрҗани фонды; 9. Билгесез автор. «Хак шәҗәрә» (Пәйгамбәрләр исемнәренең шәҗәрәсе). Университет басмаханәсе. Казан. 1894; 10. Ф.Г.Гыйрфанов. «Биләр шәһәре». Пыяла. Майлы буяу, ука. 2000; 11. Р.Сәлахетдинов. «Өйләдән соң укыла торган дога». Оргалит. Темпера. 2010; 12. Р.Насыйбуллов. «Кәүсәр» сүрәсе. Кәгазь. Акрил. 2009; 13. С.Гыйләҗетдинов. «Машалла». Кулдан ясалган кәгазь. Конгрев. 2001. 1. 2. 9 — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

Ш.не шәһәр осталары, нигездә, профессионаллар, авыл осталары да ясаган, каллиграфик язуларны еш кына имамнар, муллалар язган. Казанда Ш. махсус остаханәләрдә проф. каллиграфлар тарафыннан эшләнә, алар элекке традицияләргә үзләренең индивидуль үзенчәлекләрен дә өсти. Композициядә төп элемент булып сөлес, куфи, нәсех гарәп язуы ысуллары б-н барлыкка китерелгән язма тора. Текстта «әл-Көрси» («Тәхет),» «әл-Фәтех» («Җиңү») һ.б. сүрәләр, Аллаһны мактаучы эпитетлар файдаланыла. Кайвакыт дини язмаларга аңлатма текстлар да китерелә. *Кәгъбә*, Мәккә һәм Мәдинә мәчетләре һәм башка мөселман изге урыннары сурәтләре, Нух көймәсе, Илаһи язмалар һ.б. мотивлар рухани мәгънә белдерә. Халык Ш.е жанрына үзенчәлекле гадилек хас. Анда татар агач мәчетләре, Болгар һәм Казан мөселман архит-расы истәлекләре, авыл пейзажы, үсемлек мотивлары ясала.

Басма Ш.ләрдә әхлак, дини-фәлсәфи, тарихи, әдәби-мифологик һәм йола-көнкүреш характерындагы мәгълүмат бирелә. Алар басмаханәдә бастырыла һәм сәнгатьнең күпләп җитештерелә торган төренең берсе булып санала, Идел буе, Урал, Себер, Казакъстан һәм Урта Азия мөселманнары арасында киң таралыш ала. Н.Ф.Катанов исәпләвенчә, басма Ш.ләр 10 меңнән 48 меңгә кадәр тираж б-н бастырыла. Ш.ләрне Казанда бертуган Кәримовлар аеруча күп нәшер иткән. 19 йөз — 20 йөз башы авторлары арасында Г.*Мәхмүдов*, бертуган Әхмәтовлар, А.Абдуллин, Х.Гайнуллин, Гайфулла бине Мозаффар, Г.*Сәлиев*, *Мотаһир Яхъя*, Й.Йасари, З.*Кыямкари*, *Мөхәммәдхафиз Кучум*, М.*Хуҗасәетов*, Лотфулла ибн Гатаулла, Нургали ибне Мөхәммәд, Шәмсетдин бине Хөсәен, С.Ишалин, Ш.Рәхим һ.б. була.

1920 елларда Ш. сәнгате тыела һәм әкренләп юкка чыга. 1970 елларда күренекле татар рәссамы Б.Урманче иҗатында яңарыш ала (9 Ш.дән торган серия иҗат итә — кәгазь, тушь). 1980 еллар ахырында Ш. ясау киң колач җәя. Сюжет-композиция, төс, орнамент ягынан яңача, классик гарәп язуы ысуллары стильләштерелгән, яңа техника һәм материаллар б-н эшләнгән Ш.ләр барлыкка килә (рәссамнар З.Бикташева, С.Гыйләҗетдинов, Ф.Гыйрфанов, Ә.Исхакова, Р.Мәрданов, Р.Мөхәмматҗанов, Н.Исмәгыйлев (Нәкъкаш), Р.Насыйбуллов, В.Попов, Р.Сәлахетдинов, Р.Шәмсутов, Ч.Шәрифуллина һ.б.). 1990 нан Ш.нең ләүхә дигән төре таралыш ала (рәссамнар Л.Фәсхетдинова, А.Кудряшова, А.Липина, О.Марсова һ.б.). Аның өчен бәрхет, ефәк, күн, алтын һәм көмеш җепләр файдаланыла, аппликация техникасы, энҗе һәм сәйлән һ.б. б-н тулыландырыла. Ләүхәне күпләп эшләү «Туран Арт» фонды (Казан) остаханәләрендә җайга салына.

Ш.ләр ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Шәрекъ халыклары сәнгате Дәүләт музеенда (Мәскәү), «Мәрҗани» (Мәскәү), «Туран Арт» фондларында, шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Катанов Н.Ф. Казанско-татарские литографированные издания с именами лиц Ветхого и Нового заветов. К., 1905; Воробьёв Н.И. Материальная культура Казанских татар. К., 1930; Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.Г. Декоративно-прикладное искусство Казанских татар. М., 1990; Валеева Д.К. Шамаили // Из истории татарского народного искусства. К., 1995; Шамсутов Р.И. Искусство татарского шамаиля (сер. XIX — нач. XX вв.). К., 2001; шул ук. Слово и образ в татарском шамаиле: От прошлого до настоящего. К., 2003; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Мусульманское искусство в Волго-Уральском регионе. К., 2008.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ШӘМӘ́Й** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 15 *км* көньяктарак, Томбарлы елгасы бассейнында. 2010 елда 80 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1929 да нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Баулы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 212, 1949 да — 218, 1958 дә — 199, 1970 тә — 153, 1979 да — 109, 1989 да — 63, 2002 дә — 66 кеше.

**ШӘМӘ́К** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 27,6 *км*. Бассейнының мәйданы 259 $км^2$. Елга башы Әтнә р-ны Мәрҗән авылыннан 1,6 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы — Биектау р-ны Кирилловка авылыннан 2,5 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 60 *м*. Бассейны асимметрияле: аның уңъяк өлеше шактый зур. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Ш.нең 0,8 дән 22,1 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар, иң зурлары: Тож (10,3 *км*), Кырлай (22,1 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытындагы су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 121 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,19 $м^3/с$. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**ШӘМӘ́К** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 23 *км* көнбатыштарак, Бола елгасыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 148 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.тә мәчет, мәдрәсә, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1394 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 188 ир-ат; 1859 да — 715, 1897 дә — 1021, 1908 дә — 1212, 1920 дә — 1174, 1926 да — 986, 1938 дә — 743, 1949 да — 592, 1958 дә — 429, 1970 тә — 348, 1979 да — 360, 1989 да — 204, 2002 дә — 190 кеше.

**ШӘМӘ́К** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Олы Тилчә елгасы буенда. 2010 елда 272 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 789,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 187, 1859 да — 245, 1880 дә — 306, 1913 тә — 571, 1920 дә — 632, 1926 да — 636, 1938 дә — 603, 1949 да — 567, 1958 дә — 624, 1970 тә — 731, 1979 да — 730, 1989 да — 341, 2002 дә — 309 кеше.

**ШӘМӘ́К** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 46 *км* төньяк-көнбатыштарак, Баш-Арбаш елгасы буенда. 2010 елда 330 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты. 1619 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Ильтемирова Пустошь, Семякино исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.тә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 983,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кабык Күпер волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 82 ир-ат; 1859 да — 349, 1897 дә — 684, 1908 дә — 691, 1920 дә — 776, 1926 да — 792, 1949 да — 460, 1958 дә — 380, 1970 тә — 463, 1979 да — 387, 1989 да — 341, 2002 дә — 361 кеше.

**ШӘМӘРДӘ́Н** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 22 *км* төньяктарак урнашкан. Казан–Әгерҗе юнәлешендәге тимер юл станциясе. 2010 елда 5943 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 87%) яши. Ит комб-ты, мех ф-касы, ашлык кабул итү пр-тиесе, Шәмәрдән магистраль газүткәргечләр линия-җитештерү идарәсе. Лицей, балалар сәнгать мәк-

тәбе, балалар интернат йорты, мәдәният йорты, китапханә, участок хастаханәсе, «Яшьлек» спорт комплексы, 2 мәчет, Казан Пресвятая Богородица иконасы храмы эшли. 1913–14 елларда Казан–Екатеринбург юнәлешендәге тимер юл станциясе. Оешкан көненнән Казан губернасының Мамадыш өязе



Шәмәрдән авылы. Тимер юл вокзалы бинасы.

Яңа Чүриле волостенда. 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1922 дән — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. 1948 нең 12 маеннан — шәһәр тибындагы посёлок, 2004 нең 1 июленнән — авыллар исемлегендә. Халык саны: 1959 да — 5131, 1970 тә — 4231, 1979 да — 4387, 1989 да — 5293, 2002 дә — 5876 кеше.

**ШӘМБАЛЫКЧЫ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөя елгасы буенда. 2010 елда 181 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1699 елга кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.да мәчет, мәдрәсә, 3 су тегермәне, 3 ярма яргыч, 12 вак-төяклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1634 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 195 ир-ат; 1859 да — 929, 1897 дә — 1472, 1908 дә — 1690, 1920 дә — 1490, 1926 да — 1121, 1938 дә — 736, 1949 да — 628, 1958 дә — 549, 1970 тә — 437, 1979 да — 347, 1989 да — 243, 2002 дә — 211 кеше. Ш.да җырчы Ф.Х.*Насретдинов* туган.

**ШӘМГУ́НОВ** Роберт Шакир улы (22.10.1939, Үзбәкстан ССРның Мангыт р-ны Мангыт а.), профсоюз һәм хакимият эшлеклесе. Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1966), хакимият-хуҗалык һәм партия эшендә. 1966–68 елларда консерв з-ды инженеры, баш механигы (Газалкәнт, Үзбәкстан ССР); 1968 дән Түбән Кама нефть химиясе комб-тында. 1982–83 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында нефть һәм химия сәнәгате бүлеге башлыгы. 1983–89 да КПССның Түбән Кама шәһәр ком-ты 1 нче секретаре. 1989 дан Казанда: 1989–90 да Татарстан өлкә профсоюзлары советы рәисе, 1990–91 дә ТР ЮС рәисенең 1 нче урынбасары, 1991–93 тә РФнең монополиягә каршы һәм яңа икътисади структураларны яклау буенча дәүләт ком-тының Татарстан терр. идарәсе башлыгы. 1993 тән «Татнефтепродукт» ҖБ ген. директорының 1 нче урынбасары, 1994–98 дә ген. директоры. 1985–95 тә ТАССР, ТССР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘМИ́** Низамеддин Габдел-Васи (نظام الدين شمي) (14 йөз ахыры — 15 йөз башы), фарсы тарихчысы. Тәбризнең (Иран) шәһәр читё бистәсе Шамда туа. Багдадта яши. Урта Азия хөкемдары *Аксак Тимер* шәһәрне басып алганнан соң, аңа хезмәткә керә. 1401/02 дә Аксак Тимер Ш.гә үзенең патшалык итү тарихын язарга куша. «Зафәрнамә»не («Җиңүләр тарихы», 1404) язганда, Ш. хөкүмәт канцеляриесе документларын, яуларда катнашкан кешеләрнең сөйләгәннәрен, башка чыганакларны файдалана. Ш.нең әсәрләрендә монгол дәүләтләре һәм Аксак Тимер хөкемдарлыгы дәвере тарихыннан мәгълүматлар бар, ш.у. Аксак Тимер дәүләте б-н Алтын Урда арасындагы мөнәсәбәтләр тасвир ителә.

*Әд.:* Т и з е н г а у з е н В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. М.–Л., 1941. Т. 2. *И.Л.Измайлов.*

**ШӘМСЕТДИ́Н** әл-Кышкарый (?-1833, Мисыр), дин эшлеклесе. Бохара шәһәрендә мәдрәсәдә укуын тәмамлаганнан соң, Казан губернасындагы Ташкичү авылы мәчетенең имам-хатибы, мәдрәсә мөдәррисе. Шәрекъ мөселман илләре буйлап сәяхәт итә. Каһирә шәһәре (Мисыр) ун-тында фарсы теле укыта.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Айрат Сәлимулла улы (4.3.1963, Чүпрәле р-ны Түбән Әлмә а.), зәркәнче, ТРның халык нәфис кәсепчелеге остасы (2009). Зәркәнчелек остаханәсендә Е.В.Бакакин җитәкчелегендә укый (1985). Казан сәгать төзәтү з-дында (1985–91), «Узор» пр-тиесендә (1991–2009), 2009 елдан шәхси остаханәсендә эшли. ТР Һөнәрләр палатасы (2004), Рәссамнар берлеге (2005) әгъзасы. Әйдәп баручы проф. зәркәнчеләрнең берсе. Татар зәркәнчелек сәнгате традицияләрен дәвам итә, җепкыр техникасын — яссы (челтәрле) һәм күпертмә җепкыр, бөртекләү; уеплау, чүкеп бизәк төшерү, төсле ташлар б-н кырлау, асылташларны кысалау ысулларын үзләштерә. Нигездә, көмеш б-н эшли. Милли һәм модернистик калыпларда стильләшкән аерым бизәнү әйберләре дә, яка чылбыры, муенсалар, колак алкалары, беләзекләр, йөзекләр, балдакларны берләштергән комплектлар да эшли: «Сөембикә» гарнитуры (2004, ТР халык нәфис кәсепчелеге һәм һөнәрчелеге эшләнмәләре конкурсының 1 нче дәрәҗә дипломы), «Шәрекъ» колак алкалары һ.б. Ш. ясаган бизәнү әйберләренә татар зәркәнчелек сәнгатендә киң таралган ысул — ташлар (кызыл якут, фирәзә, аметист, ахак, гәрәбә, бәллүр, юлбарыс күзе, мәрҗән һ.б.) б-н кырланган көмеш хас. Төбәкара — «Зур Идел» (2003); бөтенроссия — «Россия-10»









А.С.Ш ә м с е т д и н о в. 1. Муенса. «Чишмә» гарнитуры. Көмеш, гәрәбә, энҗе. Челтәрле җепкыр. 2003; 2. Алка. «Ханым» гарнитуры. Көмеш, мәрҗән. Күпертмә җепкыр. 2001; 3. Алка, йөзек. «Ольга» гарнитуры. Көмеш, мәрҗән. Челтәрле җепкыр. 1995; 4. «Болгар» беләзеге. Көмеш, фирүзә, малахит. Күпертмә җепкыр. 2001.



Г.Н. Шәмсетдинов.



И.Г. Шәмсетдинов.

(Мәскәү, 2003), «Зәркән-Экспо» (Казан. 2004) бөтенроссия күргәзмәләрендә; 1 нче Бөтенроссия автор зәркәнчелек сәнгате конкурсында (Калининград ш., 2012) катнаша. Медаль б-н бүләкләнә. Халыкара ислам сәнгате фестивале лауреаты (Иран, Тәбриз, 2017).

*Әд.:* Шамсутдинов Айрат // Народные художественные промыслы и ремёсла Республики Татарстан: Каталог. К., 2005.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Әхтәм Малик улы (2.10.1946, Краснобор р-ны Девәтернә а. — 8.10.2003, Казан), инженер-технолог, техник фән. д-ры (2000), проф. (2002). Казан химия-технол. ин-тын (1973), Казан ун-тын (1983) тәмамлый. 1973–2003 елларда Казан технол. ун-тында укыта. Ш. гетероген системаларда масса күчерү процессларын тикшерә. Газ чистарту өчен югары нәтиҗәле аппаратларны, махсус җитештерүнең төп технологияләре процессларын санитар газ чистарту ысулларына тәңгәл китерү алымнарын эшләүдә катнаша. Бөтерелмә агымнарда турбулентлыкка күчүнең физик процессларын билгели, сыгылмалы валлардагы нәсызыкча тирбәнешләрнең солитон характерда булуын ачыклый. Фәнни эшләренең нәтиҗәләре ТР һәм РФ пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 18 авторлык таныклыгы бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Выбор оптимальной геометрии вихревых устройств для газожидкостных тепломассообменных аппаратов // Изв. вузов. Химия и хим. технология. 1991. Т. 34 (автордаш); Термодинамический анализ процесса концентрирования серной кислоты дымовыми газами // Промышленная энергетика. 1995. № 12 (автордаш); Энерго-технологическое комбинирование в производстве нитроэфиров // Промышленная энергетика. 2000. № 1 (автордаш).

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Валерий Гарәф улы (28.4. 1947, Хабаровск краеның Ленин р-ны Бабство а.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1994). 1962–2005 елларда «Түбәнкаманефтехим» АҖдә эшли: эшче-геодезист, мастер-технолог, смена, бүлек башлыгы, цех башлыгы урынбасары, бутилкаучук з-ды баш ин-женеры (1978). Дәүләт бүләге «Түбәнкаманефтехим» АҖдә бутилкаучук, пропилен һәм стирол оксиды җитештерүнең химик технологияләренең теоретик нигезләрен эшләүдә һәм аларны җитештерүне камилләштерүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Габделхак Габдрахман улы (17.8.1946, Алексеев р-ны Кыр Шонталысы а.), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1988), тарих фән. канд. (2006). Казан ун-тын (1972), Югары партия мәктәбен (Ленинград, 1982) тәмамлый. 1965 елда Алексеев р-ны «Таң» г-тасы хезмәткәре. 1972–76 елларда Чирмешән р-ны «Ленин юлы» г-тасында партия тормышы бүлеге мөдире. 1975–76 да «Азат хатын» ж-лында, 1976–90 да «Социалистик Татарстан» г-тасында (хәбәрче, бүлек мөдире), 1991–94 тә «Татарстан хәбәрләре» г-тасының баш мөхәррир урынбасары. 1994–96 да ТР МКның мәдәният һәм сәнгать бүлеге мөдире. 1996 дан «*Ватаным Татарстан*» г-тасы, 2003–13 тә «*Мәгариф*» ж-лы баш мөхәррире. Мәкаләләре Татарстанның иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышына багышлана. ТРның Журналистлар берлеге бүләге лауреаты (1991). Медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вливается в труд моей республики. К., 1986; Энтузиасты перестройки. К., 1990.

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Габделхәй Гыйльметдин улы (11.1.1938, Кукмара р-ны Зур Сәрдек а. — 3.5.2017, шунда ук), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1983), РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1995). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), Питрәч р-нының «Искра» к-зында, Кукмара р-нының 22 партсъезд исем. к-зында (1961 елдан) һәм «Коммунизмга» к-зында (1963 тән) баш агроном булып эшли. 1979–83 тә «Коммунизмга» к-зы («Игенче» крәстияннәр хуҗалыгы берләшмәсенә (1983–99) әверелә) рәисе. Ш. җитәкләгән елларда 60 тан артык җитештерү объекты (3,2 башка исәпләнгән дуңгыз комплексы, 1500 башка исәпләнгән мөгезле эре терлек фермасы һ.б.), соц.-мәдәни һәм көнкүреш билгеләнешендәге объектлар төзелә; торак пунктларга телефон һәм газ кертелә (Зур Сәрдек, Адай, Аш-Бужи, Купка, Чишмәбаш). 1978 ел күрсәткечләре б-н чагыштырганда 1997 дә бөртекле ашлык җитештерү 2,3 тапкыр, яшелчә — 47%ка, сөт — 29%ка, ит 10,6%ка арта. Бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 14,7 *ц* дан 46,9 *ц* га, бәрәңге — 97 *ц* дан 142,8 *ц* га, еллык уртача савым һәр сыердан 2871 *кг* нан 3958 *кг* га кадәр арта. 100 *га* а.х. файдалану җирләренә 1997 дә 405 *ц* сөт, 47,6 *ц* ит җитештерелә. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Почёт орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Габдулла Хәсән улы (1870–1936), җәмәгать һәм дин эшлеклесе. Чыгышы б-н Касыйм татарларыннан. 1898 елдан Бохара мәдрәсәсендә укый, соңыннан Голҗа шәһәрендә (Кытай) имам вазифаларын башкара. 1908 дән Мәскәүдәге 1 нче мәчет имамы ярдәмчесе, 1913 тән имамы. Мәскәү елгасы аръягы татарлары җәмәгате эшчәнлегендә зур роль уйный: 1914 тә аның турыдан-туры катнашында мөселман мәктәбе ачыла, татар хәйрия җәмгыятенең эшчәнлеге активлаша. Репрессияләнә, совет хакимиятенә каршы эшчәнлек алып баруда гаепләнә. Үлгәннән соң аклана. Ш. вафат булганнан соң, мәчет яптырыла.

*Әд.:* С а ф а р о в М. Династия имамов исторической мечети Москвы // Ислам минбаре. 2000. № 1; Х а й р е т д и н о в Д.З. Мусульманская община Москвы в XIV — начале XX вв. Н.Новгород, 2002.

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Гали Нурулла улы (22.5.1915, Казан губ., Чистай өязе Яуширмә а. — 22.7.1944, Украина ССРның Львов өлкәсе Пустомыты р-ны Пшецья Вулька авылында җирләнә), Сов. Союзы Герое (23.9.1944, үлгәннән соң), гв. лейтенанты. Пед. уч-щесен (Казан, 1935), Казан а.х. ин-тын (1938), Ульянов танк уч-щесен (1941) тәмамлый. Мәктәп директоры булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 56 гв. танк бригадасының танк ротасы командиры (3 нче гв. танк армиясенең 7 нче гв. танк корпусы). Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Житомир-Бердичев (1943–44), Проскурово-Черновцы һәм Львов-Сандомир (икесе дә — 1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең июлендә Куткож станциясе янында барган сугышларда батырлык күрсәтә: танк ротасы б-н Сож елгасындагы кичүне басып ала, Гомулец авылы янында (Украина ССРның Львов өлкәсе Пустомыты р-ны) һәлак була. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә. Чистай шәһәрендә Ш. хөрмәтенә стела куела, шәһәрнең бер урамына аның исеме бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Гарәфи (Гарәфетдин) Хөснетдин улы (21.6.1908, Казан — 30.3.1979, шунда ук), хокук белгече. Бөтенсоюз читтән торып уку юридик ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1953). 1925–29 елларда Казанның «Кызыл чүкеч» з-дында эшче. 1929–30 да Чистай кантонының 3 нче, 1 нче участогында халык тикшерүчесе. 1931–34 тә Лаеш, 1934–36 да Кукмара р-ннары халык мәхкәмәләрендә халык судьясы. 1936–37 дә ТАССР Югары мәхкәмәсе әгъзасы, 1937–41 дә рәисе. 1941–42 дә Казан гарнизоны хәрби прокуроры, 1944–45 тә хәрби прокурор урынбасары. 1942–43 тә 20 нче запас укчы бригада (Казан), 1943–44 тә 1 нче Горький запас укчы дивизия хәрби прокуроры. 1946–62 дә ТАССР МС каршындагы Дәүләт арбитражы баш арбитры. 1964–66 да Татарстан респ-ка ит сәнәгате ҖБдә юрисконсульт (хокук киңәшчесе), 1966–69 да инженер. 1970–76 да «Казаньпромстрой» тресты, 1977–78 дә «Промстрой»ның 2 нче төзү-монтаж трест юрисконсульты. 1938–47 дә ТАССР ЮС депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Илгизәр Гаптенур улы (19.8.1953, Минзәлә р-ны Калмыя а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), «Түбәнкамашин» һәм «Бөгелмәнефтемаш» з-дларында эшли. 1980–96 елларда «ВНИИнефть» Төбәк фәнни-технол. үзәге хезмәткәре, 1996–99 да Инженерлык-җитештерү үзәге инженер-конструкто-

ры, 1999 дан «ТатНИПИнефть» Татарстан фәнни-тикшеренү проектлау ин-тының скважиналардан файдалану һәм ремонтлау секторы мөдире (Бөгелмә ш.). Хезмәтләре югары үзле нефть чыгару җиһазлары булдыруга, скважиналы штанга насосларының чылбырлы күчергечләрен ясауга, скважина авызындагы хәрәкәтчән тарту органнарын герметизацияләү җайланмаларын булдыруга карый. Уйлап табуга 2 патенты бар. Дәүләт бүләге авыр чыгарыла торган нефть запасларын үзләштерүнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен яңа технологияләр һәм җиһазлар комплексы эшләүдә һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Применение глубиннонасосной установки с полыми штангами для подъёма из скважин природного битума // Нефт. хоз-во. 1990. № 12 (автордаш); Трудноизвлекаемым запасам — новую технологию // Нефть и жизнь. 2008. № 3 (автордаш).

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Исмай Гайнетдин улы (29.9.1910, Пермь губ., Верхотурье өязе Надеждинский Завод, хәзер Свердловск өлкәсе Серов ш. — 8.6.1982, Казан), композитор, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1966), ТАССРның халык артисты (1981). 1952 елда Казан консерваториясен (А.Леманда композиция классы) тәмамлый. Ш. музыкасына халыкчан җыр интонациясе, эмоциональ байлык, заманча темага мөрәҗәгать хас. 200 дән артык җыр (массакүләм, хор, лирик, патриотик җырлар); балалар өчен әсәрләр, ш.и. солистлар, катнаш хор һәм симф. оркестр өчен Ә.Ерикәй шигыренә «Пионерлар кантатасы»; камера-инструменталь әсәрләр: Кыллы квартет, Тынлы агач музыка уен кораллары өчен квартет, Фортепиано өчен сонатина, скрипка һәм фортепиано өчен «Легенда», виолончель һәм фортепиано өчен «Ария», труба һәм фортепиано өчен «Элегия», фугалар, сонатиналар, фортепиано өчен пьесалар; татар халык җырлары эшкәртмәләре һ.б. авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Композиторы Татарстана. М., 2009.

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Кәшшаф Шәйхетдин улы (8.3.1909, Пермь ш. — 1993, Казан), инженер-технолог, техник фән. канд. (1966), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1951). Казан мех техникумын (1929), Казан ун-тын (1936), СССР җиңел сәнәгатенең икееллык югары курсларын (Мәскәү, 1966) тәмамлый. 1929–60 елларда (бүленеп) Казан мех комб-тында (хәзер «Мелита» АҖ): мастер, цех башлыгы, смена инженеры, җитештерү бүлеге мөдире, үзәк химия лаб-ясе башлыгы, 2 нче ф-када җитештерү мөдире, комб-тның баш инженеры (1953 тән). СССР Дәүләт бүләге мех эшкәртү һәм буяуның катнаш ысулларын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә, бу мехның сыйфатын яхшыртырга, эшкәртү циклын 36 дан 26 җитештерү поцессына кыскартырга, җитештерү мәйданчыкларын, җиһазларын һәм 60% эшче көчне бушатырга мөмкинлек бирә. 1960–79 да ВЦСПСның Бөтенсоюз хезмәтне саклау фәнни-тикшеренү ин-ты директоры.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Наил Шакир улы (27.11.1938, Саба р-ны Тимершык а. — 9.10.2003, Казан), патологоанатом, мед. фән. д-ры (1991), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1999). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1966), шунда ук патологик анатомия кафедрасында эшли, 1989 елдан каф. мөдире, бер үк вакытта, 1969–73 тә, декан урынбасары, 1973–83 тә стомат. ф-ты деканы. Хезмәтләре селәгәй бизләрендә, аналык җинсәсендә яман шеш алды халәтенә һәм яман шеш авыруына диагноз куюның иммунологик һәм клиник ысулларын эшләүгә карый. «Ревматик васкулитка диагноз кую алымнары» ысулын уйлап тапкан өчен авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Иммуноморфологическая характеристика клеток адено-кистозной карциномы // Казан. мед. журн. 1991. № 3; Гистогенез аденолимфомы слюнных желёз // Казан. мед. журн. 1994. № 3; Структура синусов лимфатических узлов в норме и процессе метастазирования рака // Казан. мед. журн. 1996. № 4 (автордаш).

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Николай Миркамал улы (26.8.1949, Төмән өлкәсенең Ямал р-ны Яр-сале пос.), шагыйрь, тәрҗемәче, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (2011). Рус телендә яза. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1980). Нефтьче, тележурналист булып эшли. 1994 елдан Россия Язучылары берлегенең Төмән бүлеге рәисе. «Көтәргә өйрәнергә» («Выучиться ждать», Свердловск, 1980), «Яшьлек белән хушлашу» («Прощание с юностью», М., 1982), «Айлы ана болан» («Лунная важенка», М., 1985), «Ямалның киң битле алиһәләре» («Скуластые музы Ямала», М., 1987), «Җавапсыз мәхәббәт» («Любовь без утоления», Төмән, 1997), «Сургут холкы» («Сургутский характер», Екатеринбург, 1999), «Хатын-кыз йөрәге белән укый» («Женщина читает сердцем», Екатеринбург, 2000), «Яшәеш» («Жутье-бытье», Екатеринбург, 2004), «Изге фидакарьлек» («Заветная беззаветность», Екатеринбург, 2006), «Кадерле Югра» («Югра дорогая», Екатеринбург, 2010) һ.б. шигырь җыентыклары авторы. Ш. шигырьләре «гримсыз чынбарлыкка» багышлана. Шагыйрь хәзерге җәмгыять өчен әһәмиятле рухи, гуманизм, шәфкатьлелек мәсьәләләрен күтәрә. Шигырьләрендә еш кына аның б-н үзләренең шатлыклары һәм кайгылары, өметләре һәм күңел төшенкелеге б-н уртаклашучы героиняларының ышанычлы кешесе итеп сурәтләнә. Татар, авар, грузин, Америка шагыйрьләренең шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итә. Гомуммилли Горький әдәби бүләге (2007), Халыкара Волошин бүләге (2010) лауреаты.

Ә с ә р.: Избранное: В 3 т. Тюмень, 2009–11.

*С.М.Исхакова.*

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Рушан Галәф (Галәветдин) улы (25.11.1946, Казан), график, каллиграф, нәкышьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1997), ТРның халык рәссамы (2011). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1966), Мәскәү полиграфия ин-тын (1981) тәмамлый. 1963 елдан «Чаян», «Азат хатын», «Сөембикә», «Ялкын», «Мирас» (1991–93 тә бизәлеш мөхәррире) ж-ллары, «Социалистик Татарстан», «Комсомолец Татарии», «Советская Татария», «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» г-талары б-н хезмәттәшлек итә. 1970 тән «Теплоконтроль» заводының проектлау бюросында, 1975–78 дә Казан сувенирлар ф-касында рәссам. 1968 дән Татарстан китап нәшриятында рәссам, штаттан тыш рәссам (1980 нән), 1993–2007 дә бизәлеш редакциясе мөдире. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1994).



Р.Г.Шәмсетдинов.

Китап графикасы өлкәсендә әйдәп баручыларның берсе, 500 гә якын китап бизи: «Идегәй» (1994); Мөхәммәдъяр, «Нуры содур» (1997); Кол Гали, «Кыйссаи Йосыф» (1999); «С.Хәким» (2001); Ә.Фирдәүси, «Шаһнамә» (2003); М.Әмин, «Могҗизанамә» (2005); Р.Вәлиев, «Сайланма әсәрләр» (2006); Мәҗлиси, «Сәйфелмөлек» (2007); У.Шекспир, «Сайланма әсәрләр» (2007) һ.б. «Биш баһадир» (2001), «Әсирлектән кайткан әкиятләр» (2002), «Алтын сандык» (2003) һ.б. әкиятләр җыентыкларына, балалар өчен «Татар тарихы» альбомнар сериясенә (1–6 китаплар, 2002–08) иллюстрацияләр ясый. Ш. иҗаты татар халык сәнгате традицияләренә, Шәрекъ миниатюраларына хас — бизәклелек, яссылык, шартлылык, символлык, полихромия ысулларын файдалануга нигезләнә. Станлы графикада (темпера, гуашь, акварель, тушь) һәм станлы нәкышьтә тарихи шәхесләр образларының автор күзаллавындагы портретларын гәүдәләндерә: «Идел буе Болгары солтаннары» (1990–94), «Алтын Урда ханнары» (1991–99), «Казан



Р.Г.Ш ә м с е т д и н о в. «Шагыйрь Мөхәммәдъяр (1497–1552)». Кәгазь, Акварель, темпера. 1991.

ханнары» (1992–98), «Татар халкының каһарман бабалары» (1991–94), «Борынгы шагыйрьләр» (1990–96); замандашлары — ТР ФА Президенты М.Хәсәнов (1998), язучылар А.Гыйләҗев, Р.Батулла (икесе дә — 1997), шагыйрьләр М.Әгъләм (1997), Р.Миңнуллин (2010), композиторлар Р.Яхин (1997), С.Садыйкова (2006) һ.б.ның портретларын ясый. Станлы сәнгатьтә тематик картиналар, портрет, пейзаж жанрында эшли: «Монастир шәһәре. Боргуб династиясе төрбәсе», «Кайруан шәһәре. Сиди Укба мәчете»,



Р.Г.Ш ә м с е т д и н о в. «Мөхәммәд пәйгамбәр». Шәмаил. Кәгазь. Акварель, темпера. 1992.

«Мигъраҗ: Җәбраил. Мөхәммәд. Борак» (барысы да — 1999), «Алтын Урда. Хан ау вакытында» (2002), «Сөембикә һәм Үтәмешгәрәй хан. Сафагәрәй төрбәсе янында» (2003), «Галәм. Аллаһы көрсие» (2006), «16 йөздә Казан. Ак барс» (2007), «Татарстан. Ак барс» (2008), «Г. Тукай» триптихы (2010–11) һ.б. ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбленә костюм эскизлары, И.Байтирәкнең «Сәрвиназ» балетына декорация һәм костюм эскизлары иҗат итә (барысы да — 2004–05). Ш. эскизлары буенча Казан метрополитенының «Тукай мәйданы» станциясендә мозаикадан Г.Тукай әсәрләренә 19 дивар панносы эшләнә. Ш. — танылган каллиграф: «Аллаһы исеме» (1992), «Икмәкнең кадерен бел» (1998), «Галәм. Аллаһы көрсие» (2006), «Бисмилла» (2006), «Пәйгамбәрләр» (2009), «Ислам пәйгамбәрләре» темасына 27 дивар панно-шәмаилләре авторы.

Респ-ка — «Казан сувенирлары» күргәзмәсендә (1973), Китап рәссамнарының 1 нче күргәзмәсендә (1981), «Татарстан китабы сәнгате», «Яңа графика» күргәзмәләрендә (икесе дә — 2007), «Шәмаилләр күргәзмә-конкурсы»нда (барысы да — 2009); шәмаилләр күргәзмәсендә (Мәскәү, 2004), Казанның 1000 еллыгына багышланган (2005), «Г.Тукай — 125 ел» (Мәскәү, С.-Петербург, 2010); төбәкара — «Зур Идел» (1998), «Берләшү» (Түбән Новгород, 2007); халыкара — «Шүрәле һәм мин» (Казан, Мәскәү, 2011; Уфа, 2012), ТЮРКСОЙ (Төркия, Әнкара, 2012) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1993, 1995, 1996, 1999 дан 2010 га кадәр ел саен, 2012, 2016 да (Казан), 2001 дә (Чаллы), 2003 тә (Болгар) уздырыла. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Чаллы картиналар галереясында, Матбугат академиясендә (Мәскәү), Россия фән һәм мәдәният үзәгендә (Прага ш., Чехия), Россия һәм чит илләрдәге (Франция, АКШ, Төркия, Тунис, Монголия, Эстония һ.б.) шәхси тупланмаларда саклана. Кол Гали исем. халыкара (Казан, 2000), «Казан сувенирлары» конкурсы (1975), Бөтенроссия сәяси плакатлар конкурсы 1 нче бүләге (Мәскәү, 2981) лауреаты; «Гарәп каллиграфиясе» бөтенроссия конкурсы җиңүчесе. Медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: В мире истории — Тарих дөньясында — In the world of history: Графика. Живопись. Прикладное искусство: Альбом. К., 2002.

*Әд.:* Х ә л и у л л и н И. Игелекле талант // Казан утлары. 1996. № 11; М и н н е б а е в К. Вдохновлённый историей народа // Казань. 1995. № 9/10; Х а м и д у л л и н Б. Любовь. Талант. Мастерство // Идель. 2002. № 2; М а л и к о в а А. Рушан Шамсутдинов: Цвет несёт настроение // ЭТНОсфера. 2010. № 11.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Фәйзрахман Әхмәтсәлим улы (2.5.1947, Казакъстан ССРның Көнчыгыш Казакъстан өлкәсе Зайсан ш.), машиналар төзү технологиясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2007), проф. (2008). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), «КамАЗ» җитештерү берләшмәсендә эшли. 1989 елдан Кама инженерлык-икътисад академиясенең машиналар конструкцияләү нигезләре каф. мөдире. 2006 дан Казан техник ун-тында, конструкцияләү нигезләре каф. профессоры. 2008 дән Казан аграр ун-тында, гомуми инженерлык фәннәре каф. мөдире (2011 дән). Хезмәтләре материалларны эшкәртү өчен электр алымнарының яңа җиһазлары классын һәм технологиясен эшләү һәм гамәлгә кертүгә, махсус кулланышлы югары төгәллекле күчергеч системасын булдыруга карый. Контактлы өзлексез эретү алымы ярдәмендә материалларны электр б-н үлчәмле эшкәртү өчен энергия ягыннан нәтиҗәле ысул һәм җиһазлар эшли. Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар.

Х е з м.: Проектирование механических передач. Наб. Челны, 2003; Основы электрической обработки материалов контактным непрерывным оплавлением. Наб. Челны, 2005; Проектирование и расчёт пружинных элементов сельскохозяйственной техники. К., 2012 (автордаш).

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Хазбулат Хазбулат улы (12.11.1950, Казан), журналист. Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1975–76 елларда Казан телевидение студиясе мөхәррире, 1979 дан «*Вечерняя Казань*» г-тасында бүлек мөдире. 1986–89 да КПССның Казан шәһәр ком-тында бүлек мөдире урынбасары. 1989 да «Вечерняя Казань» г-тасының баш мөхәррире урынбасары, 1991 дән ген. директоры — шеф-мөхәррир. Мәкаләләре иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә карый. Ш. А.П.*Гавриловтан* калган традицияләрне дәвам итә. Хәзерге вакытта газета шәһәр мәгълүмат басмалары арасында әйдәп баручы урыннарның берсен били. Ш. вакытында газета Россия төбәкара басмаларында күп тапкырлар иң яхшысы булып санала.

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Хафиз (Хафис) Гыйниятулла улы (5.8.1903, Пенза губ., Саранск өязе Алтарово а. — 15.7.1986, Казан), балет артисты, ТАССРның атказ. артисты (1939). 20 нче елларда — Казан сәнгать техникумында (педагог Ю.Муко), Зур театр каршындагы уч-щедә укый. 1930–38 дә — Татар. акад. театры, бер үк вакытта, 1937–38 дә — Татар филармониясе, 1939–42 дә Татар опера һәм балет артисты. Бөек Ватан сугышы елларында агитбригадалар составында фронтка чыга. 1942 дә репрессияләнә. Сөргеннән кайткач (1955), ТАССР Мәдәният министрлыгы каршындагы Халык иҗаты йортында хореография буенча консультант булып эшли. Ш.ның башкаруы эмоциональлеге, югары осталыгы, җиңел һәм биеккә сикерүе б-н аерылып тора.

**ШӘМСЕТДИ́НОВ** Ясир Сафиулла улы (14.1.1918, Перовск ш., хәзер Кызылурда ш., Казакъстан — 18.11.1996, Казан), мәдәният эшлеклесе, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Җәләлабад пед. техникумын тәмамлаганнан соң (1936), шунда ук укыта. 1937 елдан Казан пед. ин-тында укый, 1944 тә Сталинабад пед. ин-тын тәмамлый. 1948 дән ТАССР Мәгариф министрлыгында, мәктәпләр инспекторы, министр урынбасары (1950 дән). 1952 дән Казан өлкәсе башкарма ком-ты халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1953 тән ТАССР мәдәният министры урынбасары. 1962 дән мәдәният хезмәткәрләре профсоюзы өлкә ком-ты рәисе, 1978 дән Казан галимнәр йорты директоры, 1991 дән Салих Сәйдәшев музее директоры. Рус, Европа, үзбәк һәм казакъ язучыларының, ш.и. А.И.Герценның «Кем гаепле?» («Кто виноват?», 1964) романын, Э.Хемингуэйның «Карт һәм диңгез» («Старик и море», 1971) повестен, дубляж өчен нәфис фильм текстларын, ш.и. 1970 елларда Э.Рязановның ТАССР телевидениесеннән күрсәтелгән «Автомобильдән саклан», Э.Кареловның «Ике иптәш хезмәт итте», В.Басовның «Калкан һәм кылыч» фильмнары текстларын татар теленә тәрҗемә итә. «Совет Татарстаны сәнгате» фильмы сценарие авторы (1950). Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ш а м о в а А.А. Первый директор музея Салиха Сайдашева // Салих Сайдашев. Величие и трагизм личности. К., 2011.

*Ә.А.Шамова.*

**ШӘМСЕТДИ́НОВА** Мәсгудә Ислам кызы (1.7.1955, БАССРның Аскын р-ны Кышлау Елга а.), композитор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993), филос. фән. канд. (2001). 1979 елда Казан консерваториясен (А.Луппов классы) тәмамлый. 1980–85 тә Казан курчак театрының музыка бүлеге мөдире, 1985–91 дә Казан телевидение студиясенең муз. мөхәррире, 1991–94 тә Казан консерваториясенең Идел буе халыклары музыкасы кабинеты мөдире. Ш.ның үзенчәлекле иҗаты татар халкының этник һәм дини башлангычына нигезләнгән: татарларның борынгы бабаларыннан килгән мәҗүсилек йолаларының берсе — «Карга боткасы»; мифлар, легендалар һәм


М.И. Шәмсетдинова.

милли тарих б-н бәйле вакыйгалар — «Мәһди» (1999), «Кыйссаи Сөембикә» (1991), «Ибне Фазлан» симфониясе (2001) һ.б. —шундыйлардан. Ш. иҗатында ислам рухи традицияләренең гәүдәләнеше аерым урын алып тора (татар композиторлык сәнгатендә беренче тапкыр): «Адәм балалары» (1993), «Кадер киче» (2000), «Корбан бәйрәме» (1992) һ.б. Ш. муз. фольклорны җыя һәм өйрәнә (татарларның этник төркемнәре көйләре, дөнья халыкларының бишек җырлары), чит илдә татар музыкасын пропагандалый. 2002 дән АКШта яши (Сиэтл ш.), бер үк вакытта Татарстанның муз. тормышында актив катнаша. 1982 дән СССР композиторлар берлеге әгъзасы. «Нәүрүз» (Казан, 2002), «Арт-Урда» (Бишкәк, Кыргызстан, 2003) һ.б. төрки театрларның Бөтенроссия һәм халыкара конкурслары һәм фестивальләре лауреаты.

Төп әсәрләре: «Дастан» (1999), «Чыңгызхан» (2004) симфонияләре; «Тукай әкиятләре» симф. сюитасы (1987); Оркестр б-н скрипка өчен концерт (1979); Һ.Такташның «Җир уллары» трагедиясе буенча солистлар, мөнәҗәтләр укучылар, хорлар һәм оркестр өчен шул исемдәге оратория (2012); тавыш, альт, вибрафон, кыңгыраулар һәм там-там өчен татар халкының туй йолалары темаларына вокаль күренешләр (1988); Г.Тукай шигырьенә «Мәхәббәт җыры» вокаль цикллары (1986), халык текстларына «Мәхәббәтнамә» (1987); камера-инструменталь әсәрләр, җырлар, драма спектакльләренә музыка.

*Әд.:* Я х о н т о в а Е.С. Йөрәк яктысы // Татарстан. 1991. № 10; Г у б а й д у л л и н а Г. ...Плюс потребность души // Советская музыка. 1989. № 11; Б о р о д о в с к а я Л.З. Исламские символы в современной татарской музыке (на примере кантаты «Дети Адама» М.Шамсутдиновой) // Музыкальная культура народов России и зарубежных стран: Страницы истории. К., 2003; Композиторы Татарстана. М., 2009. *Ф.Ш.Салитова.*

**ШӘМСЕТДИ́НОВА** Рәсимә Равил кызы (15.11.1954, Биектау р-ны Мүлмә а.), филолог, филол. фән. канд. (2000), доцент (2001). ТРның атказ. мәктәп укытучысы (2003), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), Казан пед. уч-щесендә укыта. 1980–84 елларда СССР ФА Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тының тел секторында өлкән лаборант, 1984–91 дә шул ук ин-тта кече фәнни хезмәткәр, бер үк вакытта, 1982–86 да, Казан консерваториясендә укыта; 1991–92 дә Казан ун-тының татар теле, ш.у. чит телле аудитория өчен татар теле кафедралары ассистенты, 1992–2001 дә чит телле аудитория өчен татар теле каф. өлкән укытучысы, 2001–2007 дә доценты, 2007 дән гамәли тел белеме һәм тәрҗемә белеме каф. доценты, бер үк вакытта, 2005 тән, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Мәгарифне үстерү ин-тында (2016 дан татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире; бер үк вакытта Казан ун-тының Югары журналистика мәктәбендә татар журналистикасы каф. доценты). ТР МК каршындагы Терминология комиссиясе әгъзасы (2000–08). Татар лексикологиясе һәм терминологиясенә, текстологиягә караган хезмәтләр, сүзлекләр, дәреслекләр, уку-укыту һәм методик ярдәмлекләр, уку-укыту программалары һ.б. авторы. «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы ТР Законын гамәлгә ашыруга зур өлеш кертә. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының К.Насыйри исем. респ-ка бүләге лауреаты (2009). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Әлифба. Туган телдә (татар телендә) башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен УМК. К., 2008, 2012, 2016 (автордаш); Татар теле. Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмаларының 2, 3, 5 нче сыйныфлары өчен УМК. К., 2014, 2016 (автордаш). Татарский за 20 уроков. К., 1998 (автордаш); Медицинская терминология в татарском языка. К., 2001; Русско-татарский словарь медицинских терминов. К., 2004; Краткий русско-татарско-английский толковый словарь медицинских терминов. К., 2009 (автордаш).

**ШӘМСИ́** (Шәмсетдинов) Солтан Сәлах улы (10.2.1946, Биектау р-ны Суыксу а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1996). Татар һәм рус телләрендә яза. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1977). 1977–85 елларда «Казан утлары» ж-лының проза бүлегендә мөхәррир, 1990–99 да (бүленеп) «Идел», «Татарстан» ж-лары редакцияләрендә эшли. 1993–98 дә Татарстан китап нәшриятында фәнни-популяр әдәбият редакциясе мөдире. 2000–12 дә ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында: әдәби мөхәррирләр төркеме җитәкчесе (2000–06), мөхәррир. «Көмеш чылбыр» (1984), «Җәяүле буран» (1988) хикәяләр җыентыклары, «Еллар эзе» (1996) хикәя, пьеса һәм публицистика җыентыгы, балалар өчен «Ут хәйләсе» фәлсәфи повесть-әкияте (1994; 2014) авторы. Иҗатының мөһим юнәлеше — татар тарихын популярлаштыру. Әхмәд ибне Фазланның Болгар иленә сәяхәте язмаларының әдәбиләштерелгән яңа вариантын тудыра: «Ибне Фазланның Ител елгасына сәяхәте һәм Болгарстанда ислам дине кабул итү» («Путешествие Ахмеда ибн Фадлана на реку Итиль и принятие в Булгарии ислама», М., 1992). 1999 да китапның рәсемле татарча һәм русча «Әхмәд ибне Фазланның Ител елгасына сәяхәте — Путешествие Ибн Фадлана на реку Итиль» басмасы дөнья күрә. «Идел Болгарстаны» (2001), Алтын Урда һәм төркиләр тарихына багышланган китаплар авторы. Г.Ибраһимов, М.Әмир әсәрләрен, Р.Фәхретдиннең «Алтын Урда ханнары» (1996) очерклар җыентыгын рус теленә, Н.В.Думбадзе, Р.Мирхәйдәров, Г.Матевосян һ.б. әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Татарстан Язучылар берлегенең Ф.Хөсни (2000), А.Алиш (2013) исем. премияләре лауреаты.

Ә с ә р.: Низаглы Йортта. К., 2002; Күк капусы ачылса... К., 2006; Сөт калыр, Ватан китәр. К., 2011; Тарихи әсәрләр. К., 2015; Волжская Болгария в рассказах для детей. К., 1995 (автордаш); Золотая Орда накануне распада. К., 2008; Төрки телгә ничә яшь? / Мәдәни җомга. 2019. № 12–14.

*Әд.:* Р а х м а н Р. Күпкырлы каләм иясе: С.Шәмси // Еллар эзе. К., 1996; Ә х м ә т җ а н о в М. Язучы, публицист, тәрҗемәче. К., 1998; Ә м и р х а н Р. «Бөек болгак»тан башланган фаҗига // Фәнни Татарстан. 2002. № 3–4; С в е р и г и н Р. Күңелендә галәм чиксезлеге // Казан утлары. 2016. № 2; И с л а е в Ф. Тарих төпкеленә төшкән ул // Мәдәни җомга. 2018, 16 март.

**ШӘМСИ́ЕВ** Марат Нәҗми улы (6.1.1966, Биектау р-ны Өлә а.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2010). ТР Дәүләте бүләге лауреаты (2016). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзү ин-тында, бер үк вакытта Казан ун-ты ф-лының (Яшел Үзән ш.) профессоры (2010–2015), матем. һәм механика каф. мөдире. Хезмәтләре нефть-газ гидродинамикасы өлкәсенә карый. Геол.-промысел мәгълүматларын интерпретацияләү алымнарын, углеводород чималы чыганакларын эшкәртүне контрольдә тотуның фәнни-методологик һәм технол. ысулларын эшли һәм камилләштерә.

Х е з м.: Интерпретация результатов гидродинамических исследований скважин методами регуляризации. М., 2006 (автордаш); Гидродинамические методы исследования вертикальных скважин с трещиной гидроразрыва пласта. М., 2012 (автордаш); Термогидродинамические исследования вертикальных скважин с трещиной гидравлического разрыва пласта // Теплофизика высоких температур. 2017. Т. 55, № 1 (автордаш).

**ШӘМСИМӨХӘММӘ́ТОВ** Хаҗимөгамбәр Шәмсимөхәммәт улы (19.1.1929, Бөгелмә кантоны, хәзер Азнакай р-ны Тымытык а., — 21.2.1991, шунда ук), ТАССРның, РСФСРның атказ. агрономы (1979, 1983). ТАССР А.х. министрлыгының колхоз рәисләре әзерләү буенча Татарстан урта а.х. мәктәбен (Казан, 1956), Казан а.х. ин-тын (1970) тәмамлый. 1942–91 елларда Азнакай р-нында эшли: «Авангард» к-зында, «Тельман» исем. к-зда агроном (1956 дан), «Авангард» к-зы парткомы секретаре (1957 дән), «Кызыл Байрак» (1961 дән) һәм «Авангард» (1967 дән) к-зларында агроном. Бөртекле культураларның — арыш («Чулпан»), бодай («Мишә 2», «Московская 35»), карабодай («Майская», «Идел», «Казанская крупнозернистая», «Краснострелецкая»), арпаның («Московский 2»), кузаклыларның — борчак («Труженик»), виканың («Львовская 60») яңа югары уңышлы сортларын таратуга зур өлеш кертә. Карабодай уңышы 500 *га* мәйданда 1 *га* дан 22,6 *ц* тәшкил итә (1982). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. «Авангард» к-зының мактаулы колхозчысы (1982). 1991 дә колхозның җиләк-җимеш бакчасы Ш. исеме б-н атала.

*И.Н.Афанасьев.*

**ШӘМСУ́ТОВ** Рөстәм Илшат улы (4.7.1965, Казан), архитектор, нәкышьче, график, сәнгать белгече, сәнгать фән. канд. (2000), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2013). Мәскәү архит-ра ин-тын (1991), Казан ун-тының татар филологиясе, тарихы һәм

көнчыгыш телләре ф-тын (1999) тәмамлый. 1996 елдан ТР ФАнең Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли, 2006 дан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 2007 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында архит-ра композициясе кафедрасында. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1998). Углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-ты бинасы (2001), Пушкин урамындагы



Р.И.Ш ә м с у т о в. «Дөнья яралу». Шәмаил. Графика, киндердәге басма. 2009. Фредрик де Енга коллекциясе (Нидерланд).

34 нче йорт (2008) фасадлары проектларын, «Татнефтехиминвест-Холдинг» АҖ (2004–05), Казанның Авиатөзелеш районы хакимияте бинасы (2005), Казандагы җәмәгать һәм торак бинalары, Актаныш районындагы «Нур» мәчете (2012) интерьерларын эшли.

Ш. татар шәмаилләре сәнгатен өйрәнүгә, үстерүгә һәм пропагандалауга зур өлеш кертә. «Татар шәмаиле сәнгате (XIX йөз уртасы — XX йөз башы)» («Искусство татарского шамаиля (сер. XIX — нач. XX вв.)») (2001), «Татар шәмаилендә сүз һәм образ: Үткәннән хәзергәчә» («Слово и образ в татарском шамаиле: От прошлого до настоящего») (2003) тикшеренүләре; Татар язуы



Р.И.Ш ә м с у т о в. Актаныш районы «Нур» мәчетенең эчке бизәлеше. Керамика. Мозаика, дивар бизәге. 2012.

музее концепциясе (2008), «Кол Шәриф» мәчетендә татар шәмаиле һәм каллиграфиясе экспозициясе (2010) авторы, шәмаилләр һәм каллиграфия сәнгате күргәзмәләре оештыручыларның берсе (1996, 2004, 2008, 2010, 2011, Казан; 2004, 2009 Мәскәү). Традицион нәкышь техникасында пыялада эшли, нәкышь (майлы буяу б-н) һәм график (акварель, тушь), ш.у. компьютер графикасын да кулланып, шәмаилләр ясый; ислам сәнгате стилендә станлы картиналар иҗат итә: «Әл-Борак» (1995), «Ана бүре» (1997), «Мәңгелек әйләнеш», «Казан Кремле картасы», «Сөембикә», «Мәрҗани портреты» (барысы да — 1998), «Ибне Фадлан сәяхәте» (1999), «Фәтех сүрәсе», «Аятел көрси» (икесе дә — 2000), «Җиңү» (2001), «Аллаһ — иң яхшы саклаучы», «Кәгъбә» (икесе дә — 2002), «Бөтиләр» (2008–09), «Ачкыч. Пәйгамбәр исеме» (2009) һ.б. 2010 нан керамикадан сувенир эшләнмә, аерым алганда, дивар өчен бизәкле тәлинкәләр, панно ясау б-н шөгыльләнә.

Респ-ка — «Татар шәмаилендә сүз һәм образ» (Мәскәү, 2009); бөтенроссия —



Р.И.Ш ә м с у т о в. «Сөембикә манарсы». Триптих. Үзәк өлеш. Керамик панно. 2012. «Казан Кремле» музей-саклаулыгы.

«Татар рәссамнары» (Кувейт, 2010), халыкара — «Төрки сәнгать» (Испарта ш., Әнкара ш., Төркия, 2000); каллиграфия конкурсы, «Татар декоратив тәлинкәсе» (икесе дә — Казан, 2011) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1996, 2001, 2012, 2013 тә Казанда уздырыла. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Кувейтта Ислам сәнгате үзәгендә, Мәрҗани фондында (Мәскәү), «Кок» фондында (Төркия) саклана. Бакый Урманче бүләге лауреаты (2005).

*Әд.:* Кто есть кто в науке об искусстве. Республика Татарстан: Справ. К., 1998; Н и г м а т у л л и н а Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Мусульманское искусство в Волго-Уральском регионе. К., 2008; Татарский шамаиль: слово и образ: Каталог выставки. М., 2009; Художники Татарстана: Справ. К., 2011.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ШӘМСУ́НОВ** Салих (Салихҗан) Хәбиб улы (17.6.1946, Калинин р-ны Җылан а.), юрист, хокук фән. д-ры (2005), проф. (2007), эчке эшләр хезмәте генерал-майоры (1998), ТРның, Мари Респ-касының, Калмык Респ-касының атказ. юристы (2002, 2005, 2007). Казан авиация ин-тын (1974), СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясен (Мәскәү, 1980) тәмамлый. 1964–69 елларда Казан моторлар төзү проектлау бюросында, 1969–75 тә Казан радиокомпонентлар з-дында эшли. 1975–77 дә ТАССР Эчке эшләр министрлыгының Хезмәт б-н төзәтү учреждениеләре идарәсендә бүлек башлыгы. 1980–86 да СССР Эчке эшләр министрлыгының Хезмәт б-н төзәтү учреждениеләре баш идарәсендә инженер, 1988–90 да Төзәтү эшләре баш (берләштерелгән) идарәсендә бүлек башлыгы урынбасары, 1990–91 дә СССР Эчке эшләр министрлыгының шәхси состав б-н эшләү баш идарәсендә өлкән инспектор. 1992–98 дә РФ Эчке эшләр министрлыгының Җәзалар үтәү баш идарәсендә бүлек башлыгы, идарә башлыгы урынбасары. 1998–2005 тә РФ Юстиция министрлыгының Төзәтү эшләре баш идарәсендә бүлек башлыгы. 2009–10 да РФ Юстиция министрлыгының Дәүләт теркәү палатасы департаменты директоры, 2010–11 дә Псков юридик ин-ты профессоры. 2011 дән Г.Плеханов исем. Россия икътисад ун-тының икътисади куркынычсызлык һәм җинаять эшләре-хокук каф. профессоры. Хезмәтләре җинаять эшләре хокукына, хөкем ителүчеләрнең хезмәтен оештыруга һәм хокукый яктан көйләү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Организация и правовое регулирование труда осуждённых в Республике Татарстан (1920–1990 гг.). Самара, 2001; Труд осуждённых к лишению свободы в России: организационно-правовые проблемы. Рязань, 2003; Профессионально-техническое обучение осуждённых к лишению свободы в России: социально-правовые и организационные аспекты. М., 2004; Труд и социализация личности осуждённых к лишению свободы в России. Самара, 2005.

*Е.Б.Долгов.*

**ШӘҢГӘЛЧЕ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 14 *км* көньяктарак, Кушай елгасы буенда. 2010 елда 819 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, яшелчәчелек, мөгезле эре терлек асрау. Урта һәм музыка мәктәбе, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек,



Шәңгәлче авылы мәчете.

умартачылык, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.дә мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 тимерче алачыгы, ашлык саклау-сату, 1 бакалея һәм 3 мануфактура кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2054,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афанас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 863, 1897 дә — 1204, 1906 да — 1392, 1920 дә — 1521, 1926 да — 1557, 1949 да — 823, 1958 дә — 881, 1970 тә — 956, 1979 да — 1029, 1989 да — 837, 2002 дә — 908 кеше.

**ШӘҢГӘРӘ́ЕВ** Камил Рәфыйк улы (13.5.1942, Саба р-ны Байлар Сабасы а. — 8.6.2008, Казан), җылылык физикасы белгече, техник фән. д-ры (1980), проф. (1984). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), шунда ук термодинамик һәм җылылык физикасы тикшеренүләре тармак лаб-ясендә эшли, 1970–76 да махсус двигательләр кафедрасында. 1977–2008 дә Казан технол. ун-тында: мәгълүмати-үлчәү системалары кафедрасында (1977–81), Түбән Кама ф-лының гомуми инженерлык фәннәре каф. мөдире (1981–83), физика каф. мөдире (1984–94), мәгълүматны җыю һәм эшкәртүнең автоматлаштырылган системалары каф. профессоры (1984 тән). Хезмәтләре энергия җайланмаларының су үткәргеч өлешләрендә нәстационар җылы бирүгә карый. Ш. катлаулы җылылык-газ динамикасы шартларында күчерү коэффициентын хисаплауның ярым эмпирик алымнарын эшли. Уйлап табуга авторлык таныклыклары бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Преобразователи термоэлектрические, функциональная схема контроля и регулирования температуры. К., 2007.

**«ШӘПИ́ АГА́Й»**, газета; к. «*Социализм юлы*».

**ШӘПКӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Ата елгасының (Олы Чирмешән елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,6 *км*. Бассейнының мәйданы 55 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән, Әлки р-нында ага. Елга башы Татар Шәпкәсе авылыннан көньяк-көнбатыштарак, тамагы Иске Карата авылыннан 1 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 95 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Ш.нең 1 *км* озынлыктагы 1 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 51 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 48 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык катламы 0,022 *м*³*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ШӘПКӘ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Симгә елгасы буенда. 2010 елда 149 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Шавкина исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә («Вәлиулла Ибраһимов һәм аның абыйсы сәүдә йорты»н нигезләүче, берничә конфет ф-касы хуҗасы — Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре В.Г.Ибраһимов зур уңышларга ирешә) б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1870 тә төзелә), мәктәп, 2 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 813,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Яңасала волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 415, 1897 дә — 597, 1908 дә — 700, 1920 дә — 772, 1926 да — 554, 1938 дә — 430, 1949 да — 342, 1958 дә — 318, 1970 тә — 338, 1979 да — 272, 1989 да — 189, 2002 дә — 180 кеше.

**ШӘПШЕ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 14 *км* көнчыгыштарак, Шәпше елгасы (Казансуның сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 1268 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 59%, татарлар — 37%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз уртасында Ш.дә алпавыт Н.И.Депрейс Казан губернасыннан читтә дә яхшы таныш булган ат з-дына нигез сала. 20 йөз башында Казан Богородица, Никола чиркәүләре (1801–09 һәм 1821 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1880 дә ачыла; 1869–73 тә — хосусый мәктәп), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1210,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. 1970 елларда Ш. шәһәр һәм авылны якынайту буенча тәҗрибә мәйданчыгы булып китә: монда шәһәр тибындагы торак йортлар, социаль инфраструктура объектлары төзелә. Халык саны: 1646 да — 87, 1782 дә — 253 ир-ат; 1859 да — 784, 1897 дә — 675, 1908 дә — 872, 1920 дә — 788, 1926 да — 688, 1938 дә — 540, 1949 да — 368, 1958 дә — 279, 1970 тә — 176, 1989 да — 1200, 2002 дә — 1229 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ШӘРӘ́ БИЗЛЕ́К** (Gymnadenia), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 10 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә бер төре — черки Ш.б.е (G. conopsea) бар. Кама аръягында һәм Идел алдында очрый. Урманлы аланнарда, болыннарда, сазлык кырыйларында үсә. 30–70 *см* биеклектәге үсемлек, бармак-көрәксыман тамыр бүлбеле. Яфраклары кыяк-ланцетсыман. Чәчәкләре аксыл- яки алсу-кызыл, җиңелчә канәфер исле, күп чәчәкле куе башакка җыйналган. Җимеше — тартмачык. Июнь–июльдә чәчәк ата. Июльдә җимеш бирә. Орлыктан үрчи. Дару үсемлеге. Киптерелгән яшь бүлбеләре ашказаны-эчәк трактлары авырулары вакытында бөрештергеч һәм эч йомшарту чарасы буларак, үт куыгы ялкынсынганда, агуланган очракта файдаланыла. Декоратив үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ШӘРӘ́ПОВ** Якуб Шәрәф улы (28.1.1920, Казан губ., Лаеш өязе Имәнкискә а. — 3.8.2008, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1968), проф. (1969), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1970), РФнең югары мәктәбе атказ. эшлеклесе (2003). Ташкент пед. ин-тын тәмамлый (1941). 1942 елдан Кызыл Армиядә: Воронеж (1943), 1нче Украина (1944), 1нче Белоруссия (1944–45) фронтларында (взвод командиры). 1945–46 да Германиядәге совет гаскәрләре төркеменең хөкүмәт элемтәсе буенча аерым 248 нче батальонында взвод командиры. 1946–53 тә Таҗикстан КП ҮКның агитация һәм пропаганда бүлеге лекторы. 1953 тән Таҗик ун-тында, 1959–2008 дә Казан техник ун-тында КПСС тарихы каф. мөдире (1960–90). Хезмәтләре СССРда милли мөнәсәбәтләр тарихы мәсьәләләренә, Татарстан тарихына карый. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Национальные секции РКП (б). К., 1967; История Татарстана: Методология и понятия. К., 2008 (автордаш).

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ШӘРӘ́Ф** Галимҗан Шәрәфетдин улы (29.12.1896, Казан губ., Тәтеш өязе Аксу а. — 13.1.1950, Казан), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, тел белгече. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен (1912), Казанда 2 нче реаль уч-щене (1915) тәмамлый. 1917 елга кадәр Тимер юл элемтәсе ин-тында (Петроград) укый. Әгъзалары арасында Ильяс б-н Җиһангир Алкиннар, Габдулла б-н Гани Абызовлар булган «Татар учагы» студентлар түгәрәген оештыручыларның һәм җитәкчеләренең берсе. 1 нче һәм 2 нче Бөтенрусия мөселман корылтайларына катнаша (1917). Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–18), *Идел-Урал Штатын гамәлгә кертү һәйәте* рәисе. Ш. терр. автономия (тупраклы мохтарият) концепциясен эшли, Идел-Урал Штаты, Татар-Башкорт ССР һәм ТАССР проектларының эксперты була



Г.Ш. Шәрәф.

(И.Алкин б-н бергә); ТАССРның чиктәш төбәкләр б-н чикләрен билгеләү буенча катнаш комиссия әгъзасы. Татар-Башкорт Респ-касының актив тарафдары (татар һәм башкорт халыкларының тарихи, мәдәни һәм тел буенча якынлыгына басым ясый). 1920–33 тә ТАССР ҮБК каршындагы Адм. берәмлекләр үзәк комиссиясенең гыйльми консультанты. 1919–20 дә Казан ун-ты тарих-филол. ф-ты тыңлаучысы: проф. В.А.Богородицкий җитәкчелегендә экспериментал фонетика өлкәсендә тикшеренүләр башлап җибәрә (1927 дән экспериментал лаб. ассистенты). 1921–22 дә Гыйльми үзәкнең шәркыять бүлеге б-н җитәкчелек итә. 1922–37 дә Көнчыгыш пед. ин-тында. 1 нче Бөтенсоюз тюркологлары съезды (Баку, 1926) делегаты. Съездда илдә язуны латинлаштыру мәсьәләсе карала. 1927 нең маенда И.В.Сталинга хат юллап, анда татар язуын гарәп графикасыннан латинга күчерүгә каршы фикер белдерә, чөнки аның фаразынча, мондый гамәл татар халкының күпгасырлык рухи һәм мәдәни традицияләренең онытылуы б-н нәтиҗәләнәчәк. Хаты өчен эзәрлекләүгә дучар була; гаиләсенең әгъзалары кулга алына (к. *Шәрәфләр*). СССР Төбәкчелек белеме үзәк бюросы мөхбир әгъзасы (1926 дан). Халыкара экспериментал фонетика ассоциациясенең (Вена, 1929) хакыйкый әгъзасы. Хезмәтләре тел белеменә, демографиягә, икътисади географиягә карый. Татар теле фонетикасы мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. В.А.Богородицкий б-н бергә татар телендәге сузык авазларны билгеләү һәм язуда белдерү мәсьәләсенә ачыклык кертә. Ул чорда татар тел белемендә бу мәсьәлә буенча фикер бердәмлеге булмый: берәүләр татар телендә 10 сузык бар, аларның барысын да язуда аерым хәреф б-н бирергә кирәк дип барсалар, башкалар һәрбер сузыкны аерым хәреф б-н белдерүнең зарурлыгы юк, парлыларын берләштереп тә бирү мөмкин дигән карашны алга сөрәләр. Ш. б-н Богородицкий беренче фикернең дөреслеген исбатлап чыгаралар. Ш. беренче буларак татар телендә (рус теле белән чагыштырганда) катылык-йомшаклык күренеше җәһәтеннән сузыкларны гына түгел, тартыкларны да чагыштыру кирәклеген әйтә; төрки телләрдә сингармонизм законының яңа сыйфатламасын ача, бу телләрдә тартыклар «гармониясе» барлыгын ассызыклап күрсәтә. Беренчеләрдән булып төрки-татар фонетикасы мәсьәләләрен морфологиягә бәйләп тикшерә башлый. Чит ил галимнәре Ш. хезмәтләренә югары бәя бирәләр. Г.Тукай катнашында татар әдәбиятының беренче хрестоматиясен нәшер итә («Мәктәптә әдәбият дәресләре» 1912). Репрессияләнә (1937; 1945 тә лагерьдан иреккә чыгарыла һәм, урта мәктәптә татар теле методисты һәм укытучы буларак, Апас р-нына җибәрелә.); үлгәннән соң аклана. Казанда Ш. яшәгән йортка мемориаль такта куела.

Х е з м.: Татар иле. К., 1920 (автордаш); Яңа авыл. Әлифба: 2 кис. К., 1926 (автордаш); Җөмһүрият мөнәсәбәте белән // Кызыл Армия. 1920. 16 июнь; Татар җөмһүрияте безгә нәрсә бирәчәк? // Кызыл Армия. 1920. 25 июнь; К вопросу о принятии для тюркских народностей латинского шрифта. К., 1926; Палятограммы звуков татарского языка сравнительно с русским. К., 1927; Сонорная длительность татарских гласных. К., 1928; Сравнительная характеристика татар, русских и нацменовского крестьянского хозяйства в Татарской республике. К., 1928; Очерки по экономической географии Татарской республики. К., 1931.

*Әд.:* М ә һ д и е в М. Шәрәфнең Сталинга хаты // Әлмәт таңнары. 1990. 22 май; В ә л и е в Р. Кыямәткә юл // Мирас. 1994. № 2; ш у л у к. Фаҗига. К., 1996; Ю с у п о в Ф.Ю. Деятельность Г.Шарафа в области языкознания: Сб. науч. работ. К., 1966; К а р и м у л л и н А. Татарская книга. К., 1974.

**ШӘРӘ́Ф Г. БАСМАХАНӘСЕ́**, к. «*Мәгариф*» нәшрияты.

**ШӘРӘ́Ф** Җиһангир Хәйри улы (22.12. 1898, Казан губ., Зөя өязе Кошман а. — 5.11.1947. Казан), агроном-селекция белгече, РСФСРның атказ агрономы (1946). Казан укытучылар мәктәбен (1920), Казан а.х. һәм урманчылык ин-тын(1926) тәмамлый. 1920–24 елларда ТАССР ҮБКда статист булып эшли. 1926–31 дә ТАССР Игенчелек халык комисс-тында болынчылык буенча белгеч, орлыкчылык буенча өлкән белгеч. 1931–47 дә Казан селекция станциясендә үләннәр секциясе төркеме мөдире. Болын клеверының «Казан 1» (1938), люцернаның «Казан 36» (1938), «Казан 64/95» (1942), болын тимофеевкасының «Казан»(1956) районлаштырылган сортлары авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

**ШӘРӘ́Ф** Шәфыйка Гыйльметдин кызы (30.10.1915, Казан — 27.12.2004, С.-Петербург), астроном, физика-матем. фән. д-ры (1965). 1939 елда Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң (1939), СССР ФАнең Теоретик астрономия ин-тында (Ленинград, 1986 га кадәр) эшли. Хезмәтләре Кояш системасындагы зур һәм кече планеталар хәрәкәтенең аналитик теориясен төзүгә карый. Ш. Плутонның хәрәкәт теориясен үстерә. Җир һәм Марс орбиталарындагы элементларның гасырлар дәвамындагы үзгәрешләрен һәм планеталарның шул үзгәрешләр б-н бәйле инсоляция тәрләрен тикшерә (геол. һәм климатологиядә кулланыла). Халыкара астрономия берлеге әгъзасы (1967 дән). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теория движения Плутона: В 4 ч. // Тр. Ин-та теорет. астрономии. 1955. Ч. 1, вып. 4; 1955–64. Ч. 2, вып. 10 (автордаш); Вековые изменения орбиты Земли и астрономическая теория колебаний климата // Тр. Ин-та теорет. астрономии. 1969. Вып. 14 (автордаш); Колебания солнечного облучения Марса, вызванные изменениями элементов его орбиты // Тр. Ин-та теорет. астрономии. 1977. Вып. 16 (автордаш).

**ШӘРӘФЕТДИ́Н бине́ ХИСАМЕТДИ́Н** әл-Мөслими әл-Болгари, «*Тәварихы Болгария*» («Болгар иле тарихы», чама б-н 18 йөз ахыры — 19 йөз башына карый) исемле тарихи-әдәби әсәрнең уйдырма авторы. Рисаләдән күренгәнчә, имеш, Ш.б.Х. 16 йөзнең 2 ртысында яши, Ташбилге авылында (Шәһри Болгар янында) туа, мәшһүр мөселман илаһиятчысы Тафтазани мәдрәсәсендә белем ала, китабын болгар шәехләре үтенече буенча яза. Тарихи әдәбиятта Ш.б.Х. һәм аның әсәре төрлечә кабул ителә. Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин, М.Г.Госманов һ.б. тикшеренүчеләр, «Тәварихе Болгария»дәге каршылыкларны һәм чагышмауларны күрсәтеп, әсәрне каты тәнкыйть утына алалар: Ш.б.Х. уйдырма вакыйгаларны бер китапка туплаган «иләс-миләс кеше» (Р.Фәхретдин), исемен ниндидер кабер ташыннан алып үзләштергән «надан, фанатик татар дәрвише» (М.Г.Госманов) дип тамгалана. А.Франк, М.*Кемпер* һ.б. Ш.б.Х.нең әдәби эшчәнлеген татар җәмгыятенең идеологик сферасы контекстында тикшерәләр.

*Әд.:* У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники XVII — XVIII вв. К., 1972; К е м п е р М. Суфии и учёные в Татарстане и Башкортостане: исламский дискурс под русским господством. К., 2008.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ШӘРӘФЕТДИ́НОВ** Валерий Фәхрулла улы (5.2.1946, Уфа ш.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1989), проф. (1995). Казан ун-тын тәмамлый (1970), шунда ук эшли. 1982–92 елларда Казан химик продуктлар фәнни-тикшеренү ин-ты лаб-ясе башлыгы. 1992–2000 дә Казан технол. ун-тында, теоретик механика каф. мөдире (1998 дән). 2000 нән Казан ун-тында: гомуми матем. каф. профессоры, 2001 дән — экологик системаларны модельләштерү каф. профессоры. Хезмәтләре гидродинамикага һәм нәньютон сыекчалар реологиясенә, күзәнәкле мохитләрдә фильтрлануга һәм масса алмашуына карый. Ш. нәньютон сыекчалар агымы турындагы мәсьәләләр классының төгәл чишелешен тәзи, ирекле аркылы кисемле цилиндрик торбаларда нәньютон сыеклык агымы турындагы мәсьәләләрне чишүнең һәм ш.у. катлаулы конфигурацияле күчәр симметрияле торбаларда бу агымнарны якынча исәпләү алымнарын эшли. Ярсыну таралышының тизлеге чикле булган релаксацион фильтрация модельләре классы барлыгын ачыклый. Күзәнәкле мохитләрдә саркучанлыкның кысучы киеренкелеккә бәйле булуын тәҗрибәви билгеләү алымнарын, бер һәм ике фазалы фильтрлауның ике үлчәнешле мәсьәләләрен якынча хисаплау алымнарын эшли. Суспензиянең фильтратка һәм кысылучы утырмага бүленүе турындагы мәсьәләне аналитик юл б-н чишүгә ирешә. Уйлап табуга 17 патенты һәм авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: О поверхностях разрывов в линейной релаксационной фильтрации // Динамика многофазных сред. Новосиб., 1983 (автордаш); Течение в гидрофильных капиллярах // Журн. прикладной химии. 1984. Т. 57, № 8 (автордаш); Физико-химические основы и аппаратурное оформление технологии переработки реологически сложных систем. К., 2002 (автордаш).

**ШӘРӘФЕТДИ́НОВ** Газимҗан Сәлим улы (11.10.1952, Буа р-ы Яңа Чәчкап а.), галим зоотехник, а. х. фән. д-ры (2000), проф. (2001),

ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1975). 1976–78 елларда һәм, бүленеп, 1997 дән Казан аграр ун-тында, каф. мөдире (1997 дән). 1978–80 дә ТАССР А.х. министрлыгының дәүләт нәсел үрчетү берләшмәсендә өлкән зоотехник. 1980–83 тә Бөтенсоюз читтән торып белем алу а.х. ин-тында (Мәскәү өлкәсе Балашиха ш.). 1983 тән Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының сөт терлекчелеге төркеме мөдире, 1986 дан Питрәч р-нының «Пригородный» с-зы баш зоотехнигы. 1988–96 да Казан вет. ин-тында. Хезмәтләре ТРда холмогор токымлы мөгезле эре терлек генофондын камилләштерү һәм саклау мәсьәләләренә карый. СССР ВДНХсының ике алтын, өч көмеш, бронза медальләре, РАХФАнең Вавилов исем. медале б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2008).

Х е з м.: Технология переработки, хранения и стандартизации продуктов животноводства: Учеб. пособие. К., 2000 (автордаш); Совершенствование холмогорского скота в Татарстане. М., 2001 (автордаш); Холмогорский скот Татарстана: эволюция, совершенствование и сохранение генофонда. К., 2004 (автордаш).

**ШӘРӘФЕТДИ́НОВ** Гарәфетдин Низаметдин улы (27.2.1927, Бөгелмә кантоны Бәйрәкә а. — 9.1.2012, Казан), журналист, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1979). СССР Журналистлар берлеге әгъзасы (1962). Казан ун-тын (1951), Ленинград Югары партия мәктәбен (1965) тәмамлый. 1951–55 елларда «Совет Татарстаны» г-тасы әдәби хезмәткәре. 1955–61 дә Азнакай р-ның «Кызыл Байрак» колхозында рәис. 1961 дә «Социалистик Татарстан» г-тасы редакциясендә, 1972 дә мөхәррир урынбасары. 1973–87 дә Татарстан китап нәшрияты директоры, 2000 еллар уртасына кадәр «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» г-талары б-н хезмәттәшлек итә. Мәкаләләре а.х., сәнгать, тарих, топонимика мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Чорлар алышынганда // Здравствуй, Книга! К., 1989.

**ШӘРӘФЕТДИ́НОВ** Дамир Рәүф улы (12.9.1940, Казан — 7.2.2014, шунда ук), архивчы, журналист, тарих фән. д-ры (2005), ТАССР, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1990, 2001). Казан пед. ин-тын (1963), Ленинград югары партия мәктәбен (1973) тәмамлый. 1963–74 елларда «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан» г-таларында. 1974 тән КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, 1985 тән партия архивы мөдире. 1990–91 дә «Татарстан» ж-лы баш мөхәррире. 1991 дән ТРның иң яңа тарихына караган документларны саклау һәм өйрәнү үзәге директоры. 1993–2005 тә ТР МК янындагы Баш архив идарәсе башлыгы. Бер үк вакытта, 1999 дан, Казан энергетика ин-тының тарих һәм архив эше каф. профессоры, 2003–04 тә каф. мөдире. 2002–06 да ТР Президенты янындагы геральдика советы рәисе. «*Гасырлар авазы — Эхо веков*» ж-лына нигез салучы һәм баш мөхәррире (1995 тән; ТР Дәүләт бүләге, 2011). Хезмәтләре татарлар һәм Идел-Уралда яшәүче башка халыкларның традицион мәдәниятенә, Россиядә 1920 еллардагы милли сәясәткә, чыгышлары Польшадан һәм Литвадан булган Россия гаскәр башлыкларына карый. И.Алкин, М.Солтангалиев, Татарстанның дәүләт архив хезмәте һ. б. турындагы документлар һәм материаллар җыентыкларын төзүдә катнаша. Халык бәйрәме Сабан туе тарихын тикшерүгә, татар милли көрәшен популярлаштыруга мөһим өлеш кертә. Медальләр б-н бүләкләнә. ТР Журналистлар берлеге әгъзасы (1964 тән). Почётлы архивчы (1998). «Иң яхшы журналист» конкурсы лауреаты (2003). РСФСР милли спорт төрләре остасы (1976), 1960–80 дә ТАССРның татар-башкорт көрәше федерациясе рәисе, Бөтенроссия милли спорт төрләре федерациясе президиумы әгъзасы.

Х е з м.: Традиции, рождённые жизнью. К., 1978; Комбриг Юсуф Ибрагимов: Повесть в документах. К., 1990; Сабантуй — образ жизни народа = Сабан туе — халыкның яшәеше: Науч.-попул.очерк. К., 1997; Отчизны верные сыны. К., 2001 (автордаш); Исторические корни и развитие традиционной культуры татарского народа XIX — начала XXI вв. К., 2004.

**ШӘРӘФЕТДИ́НОВ** Зиннур Тәлгать улы (24.10.1950, Аксубай р-ны Караса а. — 10.10.2002, Чаллы ш.), педагог, пед. фән. д-ры (1999), проф, (1992), ТССРның атказ. мәктәп укытучысы (1991), РФнең атказ. югары мәктәп укытучысы (1997). Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1972), 1977 елдан шунда ук эшли, 1979–83 тә пед. һәм башлангыч белем бирү методикасы ф-ты деканы, 1984–85 һәм 1988–90 да мәктәпкәчә пед. ф-ты деканы, 1983–84 тә һәм 1987–90 да мәктәпкәчә пед. һәм психол. каф. мөдире. 1990 нан Чаллы пед. ин-ты ректоры. Хезмәтләре Татарстанда пед. фикер тарихына карый.

Х е з м.: Казан лингвистика мәктәбе һәм аның педагогик традицияләре. К., 1983; История и педагогические традиции Казанской лингвистической школы. Наб. Челны, 1992.

**ШӘРӘФЕТДИ́НОВ** Рафаэль Рәүф улы (11.1.1942 — 18.3.1990, Казан), спортчы (грек-рим көрәше), СССРның мактаулы спорт остасы (1922). Казан ун-тын тәмамлый (1969). «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан), тренерлары — Н.И.*Моряшичев*, А.Г.Мазур. 1961–70 елларда ЦСКА командасында, Казакъстан, РСФСР, СССР җыелма командаларында чыгыш ясый. СССР (1960, яшүсмерләр арасында, көмеш), РСФСР (1966) чемпионатларында, Европа турнирларында, «Динамо», «Буревестник», «Локомотив» спорт җәмгыятьләренең бөтенсоюз чемпионатларында (яшьләр арасында иң җиңел авырлыкта) җиңүче (призёр). 1969–90 да ТАССР МС каршындагы Физик культура һәм спорт ком-тының Респ-ка югары спорт осталыгы мәктәбендә тренер. Ш. татар-башкорт спорт *көрәше* үсешенә өлеш кертә.

**ШӘРӘФЕТДИ́НОВ** Фәсхетдин Мөхетдин улы (3.4.1922, Бөгелмә кантоны Шөгер а. — 11.1.2005, Минзәлә ш.), бораулау мастеры, Соц. Хезмәт Герое (1966). Хезмәт эшчәнлеген 1939 елда туган авылында колхозчы буларак башлый. 1941–81 дә Шөгер, Әлмәт-Сарман, Кама, Ямаш нефть эзләү идарәләрендә, Әлмәт бораулап нефть эзләү конторасында, «Татнефтеразведка» трестының Минзәлә бораулап нефть эзләү идарәсендә эшли. 1981–90 да «Татнефть» ҖБнең Минзәлә бораулап нефть эзләү трестында мастер, өлкән инженер. Ш. җитәкләгән коллектив ТАССР терр-ясендә — 200 дән артык, Удмурт АССР-да якынча 100 нефть эзләү скважиналары бораулый. Ш. Ромашкино, Алабуга, Миңлебай, Яңа Елховой нефть чыганакларын эзләүдә катнаша (барлыгы 30 мәйданчык), яңа техник чаралар һәм технологияләрне гамәлгә кертүнең инициаторы була. Ш. җитәкчелегендәге бригада беренчеләрдән булып айга 1000 *м* га кадәр бораулау тизлегенә ирешә; ел саен план йөкләмәләрен арттырып үти, илнең нефть эзләүчеләре соц. ярышларында лидер була.


Ф.М. Шәрәфетдинов.

Герой исеме 7 еллык план (1959–65) йөкләмәләрен үтәүдәге фидакарь хезмәте һәм батырлыгы өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 1нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Әлмәт һәм Минзәлә шәһәрләрендәге Геройлар аллеяларында Ш. бюстлары, Иске Шөгер авылында барельеф, үзе яшәгән йортта мемориаль такта куелган, Минзәләдә бер урам аның исеме б-н атала. Минзәләнең төбәкне өйрәнү музеенда һәм Шөгер мәктәп музеенда Геройга багышланган экспозиция булдырылган.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; И с х а к о в М.Ш. Наш Лениногорск. К., 2005; Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006. *М.Җ.Гаитов.*

**ШӘРӘФИ́** (Шәрәфетдинов) Габдулла Шәрәфетдин улы (29.7.1926, Арча кантоны Кече Битаман а. — 7.7.1997, Казан), язучы, ТАССР, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1976, 1986). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), «Социалистик Татарстан» г-тасында бүлек мөдире, 1967 елда «Азат хатын» ж-лында җаваплы сәркәтип, мөхәррир урынбасары булып эшли. Балалар өчен «Батыр егет» (1941), «Аккошлар кайтыр әле» (1976), «Күрше малае» (1981; 2 нче басма, 1991) хикәяләр һәм повестьлар җыентыклары, «Сусыз дәрья» (1969; русчага тәрҗемәдә «Через большой Хинган», 1975; 2 нче басма, М., 1982), «Гомернең агышлары» (1986), «Тормыш арбасында» (1997) документаль повестьлар җыентыклары авторы. Бөек Ватан, совет-япон сугышларында катнаша, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ә г ъ з а м о в Ф. Кешелекле солдатлар // Казан утлары. 1970. № 2.

**ШӘРӘФИ́ЕВ** Әнвәр Җәмил улы (15.3.1935, Азнакай р-ны Урсай а.), композитор, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989), ТРның халык артисты (2010). 1966 елда Казан консерваториясен (А.Леманда компози-



Ә.Җ. Шәрәфиев.



Г.Ә. Шәрәфиев.

ция классы) тәмамлый. 1959–2009 елларда балалар музыка һәм гомуми белем бирүче мәктәпләрдә, Казанның 1 нче пед. көллиятендә укыта. Ш. әсәрләре ачык моңы, халык җырларына якынлыгы б-н аерылып тора. Аның Г.Рәхим шигыренә язылган «Уйнагыз, гармуннар!» җыры халык иҗатының шул исем. фестивале девизына әверелә (1968 дән ел саен Казанда уздырыла). Композитор иҗатында балалар өчен музыка (җырлар, фортепиано өчен пьесалар) аерым урын алып тора. Ш. вокаль-инструменталь әсәрләрдән торган 11 җыентык, ш.и. «Каеннар җиле» («Ветер берёз», 2004), «Сандугачым, былбылым» («Соловушка», 2006), «Чулпан йолдыз» (2010) җыентыкларын, 3 өлештән торган симфониетта (2010) чыгара. Төп әсәрләре: «Юллар» симф. поэмасы (1966), симф. оркестр өчен «Риваять» (1976), тынлы оркестр өчен «Яшьләр маршы» («Молодёжный марш», 1974), Кыллы квартет (1966), виолончель һәм фортепиано өчен Баллада, Серенада, Ариозо, Элегия (1972, 1979, 1981, 1982), Фортепиано өчен сонатина (1977), камера-инструменталь әсәрләр, романслар һәм җырлар (200 гә якын) һ.б. Ш. әсәрләре концерт һәм уку-укыту репертуарына керә, халыкара һәм бөтенроссия фестивальләрендә башкарыла.

*Әд.:* Ф а й з у л а е в а М. Шарафеев Анвар // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Композиторы Татарстана. М., 2009.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ШӘРӘФИ́ЕВ** Габделфәрт Әхәт улы (6.1.1951, Кукмара р-ны Яңил а. — 27.12.2014, Казан), драма актёры, ТРның халык артисты (2011). 1973 елда Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тын тәмамлый һәм Татар акад. театры труппасына кабул ителә.



Г.Ә. Ш ә р ә ф и е в Касыйм ролендә («Мылтык», З.Хәким; Гамбәр ролендә – И.Хәйруллин, Гөлфидә – Д.Нуруллина).

Татар, рус һәм чит ил драматургларының әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә 70 тән артык төрле пландагы роль башкара. Рахманов («Агыйдел», М.Әмир), Степан («Иң кырыйдагы өй», М.Сторожева), Педро («Канлы күләгәләр», Г.А.Боровик), Нургали («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Арлекин («Хатыннар гайбәте», К.Гольдони), Зәйтүн («Синең урыныңа кайттым», Р.Хәмид) кебек зур булмаган рольләре өстендә эшләгән беренче елларында ук актёр иҗади индивидуальлеген ачуга һәм югары профессиональлеген күрсәтүгә ирешә. Матур тышкы кыяфәте, сәхнәдәге мөлаемлыгы, юмор хисе, сәхнәләштерелә торган әсәрнең стилен һәм жанрын нечкә тоеп эшләү Ш.кә лирик һәм үткен



Г.Ә. Ш ә р ә ф и е в Мансур ролендә («Әлдермештән Әлмәндәр», Т.Миңнуллин; Гөлфирә ролендә – А.Гайнуллина, Әҗәл – Р.Ш.Шәрәфиев, Әлмәндәр – Ш.Биктимеров).

характерлы рольләрне дә бер үк дәрәҗәдә ышандырырлык итеп башкарырга ярдәм итә. Мәгънәсез Хәйруллин һәм импульсив Касыйм («Кишер басуы», «Мылтык», З.Хәким), дәрәҗәле Илче («Җирән чичән белән Карачәч сылу», Н.Исәнбәт), яхшы, киң күңелле Платон («Баскетболист», М.Гыйләҗев), һавалы Байморат («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт), Шәнгәрәй бай («Арбалы хатыннар», З.Зәйнуллин), Нугайби («Мин ышанам сиңа», Л.Айтуган), Зәйнулла («Люстра», И.Зәйниев), Исмәгыйль («Хан кызы Турандык», К.Гоцци), Баш сакчы («Минем исемем Кызыл», О.Памук) һ.б. образлары шундыйлардан.

*Әд.:* И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

*И.И.Илялова.*

**ШӘРӘФИ́ЕВ** Заһит Фоат улы (1.1.1956, Әлмәт р-ны Габдрахман а.), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1999), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), ТРның атказ. химигы (2007). Казан химия-технол. ин-тын (1980), Бөтенсоюз читтән торып белем бирү икътисад ин-тын (Мәскәү, 1991) тәмамлый. 1977–79 елларда комсомол эшендә. 1980–97 дә «Түбәнкаманефтехим» ҖБдә (бүленеп): участок мастеры, бүлек мөдире, ген. директор урынбасары (1991 дән). 1981–84 тә ВЛКСМның Түбән Кама шәһәр ком-тында бүлек мөдире, 1 нче, 2 нче секретарь. 1997–2000 дә «Түбәнкама техник углеводород заводы» АҖ ген. директоры. 2000–02 дә «Түбәнкамашин» АҖ ген. директоры урынбасары. 2002 дән «Татнефть» АҖ ген. директоры урынбасары, бер үк вакытта «Татнефть-Нефтехим» идарәче компания» ҖЧҖ директоры. Уйлап табуга 2 патенты бар. Дәүләт бүләге «Түбәнкамашин» АҖдә көндәшлеккә сәләтле радиаль шиннар җитештерү технологиясен камилләштерү өчен сыйфатлы яңа материалларны эшләүдә һәм үзләштерүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘРӘФИ́ЕВ** Исмәгыйль Сәлман улы (12.11.1950, Казан — 22.6.2017, Казан, Әтнәдә җирләнә), журналист, ТРның, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (2000, 2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), «Социалистик Татарстан» г-тасында эшли. 1974 елдан «Татарстан яшьләре» г-тасында (бүленеп, 1989–90 да «Идел» ж-лында җаваплы сәркәтип), хатлар бүлеге мөдире, җаваплы сәркәтип, баш мөхәррир урынбасары, баш мөхәррир (1990 нан). Иҗтимагый-сәяси темага караган, татар мәдәнияте үсеше мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләр авторы.

**ШӘРӘФИ́ЕВ** Мансур Шәйхетдин улы (21.9.1938, Кама Тамагы р-ны Кармалы а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1983). Тәтеш совхоз-техникумын (1968), Казан а.х. ин-тын (1976) тәмамлый. 1953–99 елларда Кама Тамагы р-ның «Кама» к-зында эшли (1965 тән рәис). Ш. җитәкләгән елларда колхозда 58 җитештерү, соц.-мәдәни һәм көнкүреш объектлары төзелә; Уразлы, Кече Кармалы, Салтыган авылларына газ кертелә. Бөртеклеләр җитештерү — 2 тапкыр, сөт — 1,9, ит — 3,4 тапкыр, бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 5,7 *ц* дан 15,5 *ц* га, еллык савым уртача һәр сыердан 2093 *кг* нан 3316 *кг* га кадәр арта. 100 *га* а.х. җирләренә 730,5 *ц* сөт җитештерелә (1998). Почёт ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘРӘФИ́ЕВ** Равил Шиһап улы (5.4.1938, Балык Бистәсе р-ны Олы Солтан а.), драма актёры, ТАССРның һәм РСФСРның халык артисты (1978, 1988). 1961 елда М.С.Щепкин исем. Югары театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (Мәскәү), Татар акад. театрын-



Р.Ш. Ш ә р ә ф и е в Хәбибрахман ролендә («Беренче театр», Г.Камал).


Р.Ш.Шәрәфиев.

да эшли. Беренче елларда ук Ш.нең актёрлык осталыгы, эпизодик рольләр тудырганда, чагыштырмача зур булмаган драматургия материалында тәмамланган бөтен образ төзү сәләте ачыла. Актёрның тикшерүче Иван Васильевич («Чаткылар», Т.Гыйззәт), Әкми («Гөлҗамал», Н.Исәнбәт), Михаил («Гүзәлем Әсәл», Ч.Айтматов повесте буенча), Яхъя («Без аерылышмабыз», Ш.Шаһгали), Сөендек («Зөбәйдә — адәм баласы», Ш.Хөсәенов) кебек рольләре аның иҗат үзенчәлеген билгеләүче, ирония б-н гәүдәләндерелгән Искәндәр («Американ», К.Тинчурин, 1969) образын тудыру өчен җирлек булып тора. Ш. — иң гаҗәп, көтелмәгән хәлләрдә дә дөреслеккә туры килгән, ышандырырлык образлар иҗат итү остасы. Аның башкаруында комсыз Подхалюзин («Агай-эне — ак мыек», А.Н.Островский, 1972), хәйләкәр, үз максатын гына кайгыртучы Сиражетдин («Банкрот», Г.Камал, 1979), яраклашучан Кочкарбаев («Ахырзаман», Ч.Айтматов романы буенча, 1987) рольләре — шуның ачык мисаллары. Ш. иҗат иткән образлар арасында Әҗәл («Әлдермештән Әлмәндәр», Т.Миңнуллин, 1976) аерым урын алып тора. Актёр, әлеге символик образны кешегә хас булган соклану, икеләнү, кызгану кебек сыйфатлар б-н баетып, аның фәлсәфи тирәнлеген һәм пьесаның идея-мәгънәсен тулы ача. Аның башкаруында Насретдин («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт, 1990) образы чын халыкчан герой буларак гәүдәләнә. Бу образ аркылы актёрның халык тормышын тирәнтен белүе күренә һәм гаять оста башкару сәләте ачыла. Ш.кә хас эчке аристократизм, рухи бөеклек аның граф Альмавива («Фигароның өйләнүе», П.Бомарше, 1970), герцог Винченцо, Петруччо («Чамасына күрә чарасы», «Тискәрегә авызлык», У.Шекспир, 1968, 1986) рольләрендә дә ачык чагыла. Ш. комедия рольләрен дә, драматик рольләрне дә бер үк дәрәҗәдә оста башкара. Театр сәхнәсендә Хәбибрахман («Беренче театр», Г.Камал), Балтаев, Гайнетдин («Зифа», «Качаклар», Н.Исәнбәт), Галәви («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Рафис, Исмәгыйль («Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз», «Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин), Мәрданша («Су төбендә сөйгәнем», З.Хәким), Робинзон («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский), Антонио («Гаугалы гаилә», Э. де Филиппо) кебек истә калырлык образлар тудыра. Актёр катлаулы психол. пландагы рольләрне дә оста уйный. Аның башкаруында Фёдор Таланов («Ябырылу», Л.М.Леонов, 1980) образы тамашачыда геройның фаҗигале язмышына әрнү хисе уята;


Р.Ш.Шәрәфиев Искәндәр ролендә («Американ», К.Тинчурин; Мәйсәрә ролендә – Ф.Әхтәмова).


Р.Ш.Шәрәфиев Сиражетдин ролендә («Банкрот», Г.Камал; Камалетдин ролендә – Н.Дунаев, Җамалетдин – Ә.Шакиров).

икейөзле, мәкерле Хаҗи бәк («Кол Гали», Н.Фәттах, 1974) караңгы символик фигура буларак күзаллана. Ш.нең иҗади мөмкинлекләр диапазоны чиксез киң. Аның иҗаты эчтәлеге б-н дә, формасы ягыннан да халыкчан. Ул ш.у. Корок («Кара чикмән», Г.Хугаев), Басилио («Тәкъдир», П.Кальдерон), кенәз Пантиашвили («Ханума», А.Цагарели), Кара Гобәй («Арбалы хатыннар», З.Зәйнуллин), Вәлиулла («Ут күршеләр», С.Юзеев), Әнсәр («Бабайлар чуагы», И.Зәйниев), Сәлахетдин («Мулла», Т.Миңнуллин), Карт («Сөясеңме, сөймисеңме...», Ф.Бүләков) рольләрен зур уңыш б-н башкара һәм тамашачы ихтирамын казана. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1978), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1992) лауреаты. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Иляловa И. Театр имени Камала. К., 1986; шул ук. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

*И.И.Илялова.*

**ШӘРӘФИ́ЕВ** Сәет Минһаҗетдин улы (3.1.1906, Вятка губ., Алабуга өязе Песәй а. — 1975, Казан), дәүләт эшлеклесе. Алабуга пед. техникумын (1922), ВКП(б) ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1954) тәмамлый. 1925 елдан Алабуга һәм Арча кантоннарында (р-ннарында) хакимият-хуҗалык эшендә. 1937–42 дә ТАССР финанс халык комиссары, 1951–57 дә — ТАССР финанс министры. 1943 тән ХКС рәисе, 1946–50 дә, 1957–59 да ТАССР МС рәисе. Ш. Татарстан икътисадын хәрби тәртипкә салу эшенә, сугыштан соңгы чорда халык хуҗалыгын торгызуга, ш.у. респ-када нефть сәнәгатен формалаштыруга һәм үстерүгә мөһим өлеш кертә. 1937–54 тә, 1958–62 дә СССР ЮС, 1938–51 дә, 1955–59 да ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Вахитов И. Кремль и власть // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1998. № 3/4.

*Ф.Г.Миңнеханов.*


Ф.М.Шәрәфиев.


Р.Д.Шәрәфиева.

**ШӘРӘФИ́ЕВ** Фатыйх Миңнехан улы (20.7.1923, Оренбург губ. Яңа Якуб а. — 6.9.1985, Казан), драма актёры, кинорежиссёр, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1969), ТАССРның халык артисты (1973). Татар театр уч-щесен тәмамлый (1950). Сәхнә эшчәнлеген 1946 елда Казан курчак театрында башлап җибәрә, 1950–52 дә — Татар респ-ка күчмә театры, 1952 дән — Татар акад. театры актёры. Татар, рус һәм чит ил пьесалары буенча куелган спектакльләрдә 80 гә якын роль башкара. Театр сәхнәсендә Сергей («Профессор кияве», Ш.Хөсәенов), Врач («Киек каз юлы», А.Гыйләҗев), Госман («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит) һ.б. истә калырлык образлар тудыра. 1962 дән Казан кинохроника студиясендә: Ш. җитәкчелегендә Идел һәм Урал буе халыкларының 400 дән артык нәфис фильмы татар телендә һәм башка телләрдә дубльләштерелә. Әдәби иҗат б-н шөгыльләнә, танылган татар актёрына багышланган «Касыйм Шамил» китабы авторы (1969). Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*И.И.Илялова.*

**ШӘРӘФИ́ЕВА** Резидә Дамир кызы (10.1.1966, Минзәлә р-ны Наратлы Кичү а.), җырчы (меццо-сопрано), ТРның халык артисты (2016). 2003 елда Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тының театр бүлеген тәмамлый. 1995–2001 дә «КамАЗ» мәдәният йортының (Чаллы ш.) «Сердәш» ансамблендә, 2001 дән «Казан» милли мәдәният үзәгендә солист. Ш. актив концерт эшчәнлеге алып бара. Татарстанда, Россиядә һәм чит илләрдә (Германия, Төркия, Литва, Үзбәкстан) чыгышлар ясый. Репертуарында «Синсез яшәү — яшәү түгел» (И.Гомәров көе һәм шигыре), «Торналар киткәндә» (З.Хәйретдинов көе, Н.Камалов шигыре), «Бер тотырып карадың» (Р.Тимербаев көе, Ф.Суфияров шигыре), «Язмышым серләре» (Г.Сабирова көе

һәм шигыре) һ.б. җырлар бар. Халыкара «Татар җыры» эстрада фестивале лауреаты (2000–2002, 2008, 2009, 2011).

**ШӘРӘФИСЛА́МОВ** Фоат Шакир улы (29.9.1925, БАССРның Тәтешле р-ны Илмәт а. — 5.11.1981, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1969), проф. (1970), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1980). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), шунда ук эшли. 1952 елдан Благовещенск мед. ин-тының (Амур өлкәсе) топографик анатомия һәм оператив хирургия кафедрасында. 1958 дән Казан ГИДУВында, 1968 дән оператив хирургия һәм топографик анатомия каф. мөдире. Лимфология тәгълиматына нигез салучыларның берсе. Мед. дөньясында беренче буларак, күкрәктәге лимфа юлларына дренаж операциясен, лимфа б-н вена анастомозы операциясен («Шәрәфисламов операциясе») эшли. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лимфатическая система при некоторых острых хирургических заболеваниях брюшной полости: Учеб. пособие. Л.,1976 (автордаш); Новокаиновые блокады вегетативной нервной системы. А.-А., 1981 (автордаш); Топографо-анатомические основы акупунктуры. А.-А.,1988 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Фоат Шакирович Шарафисламов // Казан. мед. журн. 1982. № 2.

**ШӘРӘФЛӘ́Р**, бертуганнар; җәмәгать һәм дин эшлеклеләре. Күп кенә татар әдәбияты классикларының (Г.Тукай, М.Гафури, Н.Думави һ.б.) тәүге әсәрләре басылып чыккан «Матбагаи Шәрәф» басмаханәсе (1905–19, 1913 елдан — «*Мәгариф*») хуҗалары. 1) **Шиһап Шәрәфетдин улы** (1875, Казан губернасының Тәтеш өязе Аксу а. — 31.10.1939, Казан), мулла. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен (Казан) тәмамлый. Бертуган кардәшләре ярдәме б-н туган авылында мәктәп салдыра. 1922–23 тә Тәтеш кантоны азык-төлек комиссары; Аксу авылында кулланучылар кооперативларын оештыручыларның берсе. 1930 да кулак сыйфатында мал-мөлкәтеннән мәхрүм ителә. Репрессияләнә. 1931 дә төрмәгә утыртыла, 1934 тә иреккә чыгарыла; үлгәннән соң аклана; 2) **Шәһәретдин Шәрәфетдин улы** (1879, Аксу а. — 17.6.1938, Уфа), укытучы, язучы. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң (1898), шунда ук тарих укыта (1919 га кадәр). 1930 елларда Эчке Россия Диния нәзарәтенең казначысы. Ш.Мәрҗани турындагы, гарәп шигыре төзелеше, ислам тарихы («Гасыры сәгадәт: Пәйгамбәребезнең әхвәле вә исламның зоһуры хакында — «Бәхет гасыры: Пәйгамбәребезнең хәл-әхвәле һәм исламның тууы хакында», 1909; «Әсхабе Кирам» — «Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәхабәләре», 1913 һ.б.) буенча хезмәтләр авторы. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана; 3) **Борһан Шәрәфетдин улы** (1883, Аксу а. — 28.12.1942, Яшел Үзән р-ны, Раифа хезмәт б-н төзәтү лагеры), журналист, әдәби тәнкыйтьче, укытучы. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый; 1899–1905 тә шунда ук тел белеме, матем. укыта. 1905–17 дә «Казан мөхбире», «Әхбар», «Вакыт» г-талары, «Шура» һ.б. ж-ллар б-н хезмәттәшлек итә. Иранда буржуаз-демократик рев-ция булган елларда (1905–11) «Вакыт» г-тасының хәбәрчесе сыйфатында анда барып кайта (1909): нәтиҗәдә, «Иран мәктүпләре» исемле репортажлар тезмәсе бастырып чыгара. Язмаларында ул, Иран инкыйлабын сурәтләп, революцияләр халык өметләрен акламый, торгынлыкка китерә дигән фикерне алга сөрә. 1917 дә Оренбург мөселман бюросы рәисе, аның басма органы («Оренбург мөселман бюросы хәбәрләре» г-тасы) баш мөхәррире. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–18). 1917–23 тә Оренбург халык мәгарифе ин-тында (элекке «Хөсәения» мәдрәсәсе) укыта. 1930 дан Урта Азиядә наширлек эшендә. Оренбург бае һәм меценаты Гани Хөсәенов турында әсәр яза («Гани бай: Тәрҗемәи хәле, мәктүпләре вә аның хакында хатирәләр», Оренбург, 1913). Репрессияләнә (1932), 3 елга иреккән мәхрүм ителә, 1937 дә кабат кулга алына; үлгәннән соң аклана; 4) **Гыйльметдин Шәрәфетдин улы** (1885, Аксу а. — 5.1.1942, Красноярск краеның Решеты ст.), китап нашире. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый (1905 кә кадәр). «Матбагаи Шәрәф»не оештыруда һәм аны идарә итүдә төп роль уйный; «Шигърият китапханәсе» исеме б-н татар шагыйрьләренең әсәрләрен җыентыклар сериясе итеп чыгара. Г.Тукай аның кыйммәтен тәкъдир итә. 1917 дә Тәтеш өязе мөселманнарының Казан оешмасы рәисе, «Тәтеш оешмасы» г-тасы мөхәррире, Милли Шура әгъзасы. 1920 елларда Казанда Татар хосусый коммерция банкы идарәчесе урынбасары (1927 гә кадәр), аның идарәсе әгъзасы. Нэп сәясәте бетүгә йөз тоткан елларда (1920 еллар ахыры) актив наширлек эшчәнлеге өчен аны «китап нэпманы» дип йөртәләр. Репрессияләнә (1927), Орёл губернасына сөрелә, 1930 да (срогы бетеп килгәндә) 3 елга Татарстан һәм Башкортстан АССРларда яшәү хокукыннан мәхрүм ителә. 1930 дан Ленинградта, «Урман» урман сәнәгате хуҗалыгының эш оештыручысы, аннан соң «Ленпромстрой»да бухгалтер. 1938 дә кабат кулга алынып, Себергә сөрелә; үлгәннән соң аклана. Ш.у.к. *Шәрәф* Г.Ш., *Шәрәф* Ш.Г., *Шәрәф Г. басмаханәсе*.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А. Татарская книга. К., 1974; В ә л и е в Р. Фаҗига. К., 1996.

**ШӘРБӘ́Н** елгасы, Көнбатыш Кама арьягында, Кирәмәт елгасының (Кече Сөлчә, Олы Чирмешән елгалары бассейны) уң кушылдыгы, Идел арьягы түбәнлегеннән, Аксубай р-ны терр-ясеннән ага. Озынлыгы 13 *км*. Бассейнының мәйданы 72,7 *км*². Елга башы урман массивында, Нурлат р-ны Кызыл Юл посёлогыннан төньяктарак, тамагы Аксубай р-ны Яңа Дума авылының төньяк читендә. Елга башының абс. биеклеге 185 *м*, тамагыныкы — 92 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. Ш.нең 0,6 дан 6 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Озак вакыт яңгырлар булмаганда, елганың кайбер урыннары кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 95 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,035 *м*³*/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 0,72 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШӘРБӘ́Н** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 14 *км* көнбатыштарак, Шәрбән елгасы буенда. 2010 елда 443 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 еллар тирәсендә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.дә 2 мәчет, мәктәп, җил тегермәне, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1944 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Мукшы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 134 ир-ат; 1859 да — 866, 1897 дә — 1265, 1908 дә — 1472, 1920 дә — 1687, 1926 да — 1216, 1938 дә — 1119, 1949 да — 937, 1958 дә — 931, 1970 тә — 1047, 1979 да — 821, 1989 да — 570, 2002 дә — 503 кеше. Ш. тирәсендә 2 Болгар шәһәрлеге хәрабәләре сакланган.

**«ШӘРЕ́КЪ»**, к. «*Шәрекъ матбагасы*».

**«ШӘРЕ́КЪ»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм фәнни журнал. Азчылык милләтләр эше комис-тының татар бүлеге органы. 1919 елның июненнән Ташкент шәһәрендә татар телендә атнага 1 тапкыр нәшер ителә, барысы 10 саны чыга. Мөхәррире — И.Таһири.

**ШӘРЕ́КЪ АКАДЕ́МИЯСЕ**, Казандагы югары уку йорты. ТАССР Мәгариф халык комис-тының 1920 елның 30 декабрь карары б-н (чынлыкта 1921нең көзендә *Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография институты* җирлегендә ачыла) Идел буе милли һәм татар мәктәпләре өчен пед. кадрлар, музей хезмәткәрләре, адм. кадрлар әзерләү өчен булдырыла. *Казан укытучылар семинариясе* һәм «*Мөхәммәдия*» мәдрәсәсенең элеккеге биналарында урнаша. Тарих-археол., этнография, тел (төрек-татар һәм фин-угор телләре разрядлары б-н), социаль-икътисади бүлекләре була. Уку вакыты — 3 ел. 1922 гә 107 студент укый.

1922 дә Ш.а. *Шәрекъ-педагогика институты составына* керә. Укытучылар: В.А.*Богородицкий*, Г.С.*Гобәйдуллин*, Җ.*Вәлиди*, Н.Ф.*Катанов*, С.Е.*Малов*, М.Г.*Худяков*, Г.Ш.*Шәрәф*, Г.*Рәхим*, К.И.Сотонин, А.А.Хури.

*Әд.:* В и ш н е в с к и й Б. Восточная академия, ее организация и задачи // Вестн. просвещения. К., 1921. № 4–5; Х у д я к о в М.Г. Восточная ака-

демия (планы работы и условия приёма) // Изв. ТатЦИКа. 1921. 25 авг.; В а л е е в Р.М. Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX — 20-е гг. XX вв.). К., 1998.

**ШӘРЕ́КЪ БҮЛЕГЕ́**, Казан ун-тының фәлсәфә ф-ты составында көнчыгыш телләр разряды, укыту-фәнни бүлекчәсе. Россиядә беренче Көнчыгышны өйрәнү учреждениесе. 1807 елда Шәрекъ телләрен өйрәнү өчен оештырыла. 1807 дә император Александр I указы буенча университетта көнчыгыш телләр кафедрасы барлыкка килә, аны Росток ун-ты профессоры Х.М.*Френ* җитәкли. Кафедрада татар, гарәп, фарсы, яһүд һәм сүрия телләре укытыла, палеография һәм Алтын Урда нумизматикасы буенча курслар кертелә. 1807 дә Х.М.Френ беренчеләрдән булып гарәп телен укыту программасын төзи, ә 1809 да И.И.*Хәлфинның* «Гарәпчә уку кагыйдәләре белән татар теле әлифбасы һәм грамматикасы» басыла, ул 1812 дә татар теле лекторы итеп сайлана. 1817–18 елларда Я.О.*Ярцов* Шәрекъ мөселман илләренә Россиядә беренче университет фәнни командировкасын гамәлгә ашыра. 1833 нең апрелендә университет шәркыять гыйлемен формалаштыру һәм үстерү программасы кабул итә. Анда Казан ун-тының көнчыгыш телләрне өйрәнүдә әһәмиятле урын тотуы ассызыклана, шәркыятьче студентларны грек телен өйрәнүдән азат итү, ә өч еллык акад. курстан һәм сынаудан соң, шәрекъ телләрен камилләштерү максатында, университетта тагын 2 елга калдыру тәкъдиме кертелә. 1833 нең 11 маенда халык мәгарифе министры С.С.Уваров «Казан университетында көнчыгыш телләр өйрәнүчеләр өчен кагыйдәләр»не раслый, Казан ун-тында көнчыгыш телләрне гамәли һәм теоретик яктан өйрәнүнең өстәмә 2 курсын кертү турында указга кул куя. 1835 нең 26 июлендә «Россия Император университетларының гомуми уставы» кабул ителгәннән соң, Казан ун-тының фәлсәфә ф-ты программасына гарәп, фарсы, төрек-татар һәм монгол телләре кертелә. 1820–40 елларда Ш.б. тәмам оешып җитә.

1828 дә көнчыгыш телләр каф. җирлегендә ике беренче махсуслашкан төрек-татар (1846 га кадәр проф. М.К.Казимбәк, 1846 дан проф. И.Н.Березин җитәкли) һәм гарәп-фарсы телләре (1845 кә кадәр — проф. Ф.И.Эрдман, 1846–49 да — М.К.Казимбәк, 1849–55 тә проф. И.Ф.Готвальд җитәкли) кафедралары оештырыла. 1833 нең 25 июлендә Россиядә һәм Европада беренче монгол телләре каф. төзелә (проф. О.М.Ковалевский җитәкли). 1837 нең маенда Россиядә беренче кытай теле һәм тел белеме каф. ачыла, 1844 тә кытай-маньчжур каф. итеп үзгәртелә (1844 кә кадәр проф. Д.П.Сивиллов — архимандрит Даниил, 1844–50 дә — Казанда фәнни маньчжур тел белеменә нигез салучы проф. И.П.Войцеховский, 1851–55 тә проф. В.П.Васильев җитәкли). 1842 дә ике яңа кафедра — әрмән теле (мәгърифәтче-галим С.И.Назарьянц җитәкли) һәм санскритология (мөдире — П.Я.Петров) кафедралары оештырыла. 1846 да калмык теле каф. ачыла (А.В.Попов җитәкли). Алга таба Һиндстан, Тибет һәм Европа телләрен өйрәнү буенча тагын өч яңа көнчыгыш каф. ачу планлаштырыла. Ш.б. составында барлыгы 6 каф. исәпләнә: гарәп-фарсы, төрек-татар, монгол телләре, кытай-маньчжур, санскритология, әрмән һәм калмык телләре.

Профессорлар б-н беррәттән, Ш.б.дә дәресләрне көнчыгыш телләр лекторлары һәм укытучылары А.Мир-Моминов (фарсы теле, 1839–45), А.Сосницкий (кытай теле, 1840–43), С.Рушко (кытай теле, 1843 тән), И.Жуков (гарәп теле, 1843–47), М.-Г.Мәхмүдов (көнчыгыш каллиграфиясе, 1843–55), Габдесаттар Казимбәк (төрек-татар, фарсы телләре, 1845–55), И.Иванов (фарсы теле, 1845–50), М.Навроцкий (гарәп теле, 1846 дан), Н.Сонин (фарсы теле, 1846 дан), И.Холмогоров (гарәп һәм фарсы телләре, 1849–52), Г.Гладышев (әрмән теле, 1843–53), И.Габдекәримов (кытай теле, 1853–55) һ.б. алып бара. Ш.б. профессорлары һәм укытучылары мөселман Шәрегы, Үзәк һәм Көньяк Азия халыклары тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүдә мөһим роль уйныйлар. Ш.б. каршында архив һәм китапханә була. 1851 дә Ш.б. тарих ф-ты составына керә. 1855 тә Петербург ун-тына күчерелә. Ш.у.к. *Шәркыять гыйлеме*.

*Әд.:* Ш о ф м а н А.С., Ш а м о в Г.Ф. Восточный разряд Казанского университета // Очерки по истории русского востоковедения. М., 1956. Сб. 2; М а з и т о в а Н.А. Изучение Ближнего и Среднего Востока в Казанском университете (первая половина XIX века). К., 1972; Д а н ц и г Б.М. Ближний Восток в русской науке и литературе: Дооктябрьский период. М., 1973; Б а р т о л ь д В.В. Сочинения. М., 1977. Т. 9; К о н о н о в А.Н. История изучения тюркских языков в России: Дооктябрьский период. М., 1982; История отечественного востоковедения до середины XIX века. М., 1990; М и х а й л о в а С.М. Казанский университет в духовной культуре народов Востока России. К., 1991; В а л е е в Р.М. Казанское востоковедение: Истоки и развитие (XIX в. — 20-е гг. XX в.). К., 1998.

*Р.М.Вәлиев.*

**ШӘРЕ́КЪ ЙОЛДЫЗЫ́**, к. *Восточная Звезда* авылы.

**ШӘРЕ́КЪ КЛУБЫ́**, Казанда татар интеллигенциясенең мәдәният үзәге. 1907 елның 1 декабрендә ачыла. Проф. клубларга охшатып оештырыла. Устав буенча Өлкәннәр советы кул астында эшли. Идарә рәисе И.В.Терегулов. Советка Г.Әхмәров, М.Корбангалиев, Г.Камал, Г.Колахмәтов, Ф.Сәйфи, Г.Кариев, М.Мостафин, Ә.Урманчиев, Ә.Хәсәни, Г.Шәраф, Ш.Әхмәров, сәүдәгәрләр вәкилләре Ф.Әхмәтҗанов, Т.Юнысов һ.б. керә. Клуб каршында китапханә, кыллы оркестр, уку һәм тамаша заллары эшләп килә. Ш.к.нда әдәби кичәләр уздырыла, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал һ.б. чыгыш ясый, лекцияләр укыла, татар һәм рус телләрендә спектакльләр куела. 1911 гә кадәр Ш.к. «Болгар» кунакханәсендә, сәүдәгәрләр, приказчиклар һ.б клубларында вакытлыча бүлмәләр алып тора. 1911 дән М.М.Апанаева йортында урнаша. «Сәйяр» труппасының даими базасы булып хезмәт итә. 1915 тә Ш.к. бинасы госпиталь өчен бирелә һәм ул яшәүдән туктый. Ш.к. Казанның татар интеллигенциясе мәдәни тормышында мөһим роль уйный.

*Әд.:* М и ң н у л л и н Җ. Шәрык клубы: тарихи очерк. К., 2013; Б л а г о в Ю.А. К истории «Восточного клуба» // Татарстан. 1997. № 5.

**ШӘРЕ́КЪ КОНСЕРВАТО́РИЯСЕ**. 1921 елның 23 июлендә Казанда Югары шәрекъ музыка мәктәбе (1919 да музыка уч-щесе җирлегендә ачылган Үзәк шәрекъ музыка мәктәбеннән барлыкка килә) җирлегендә ачыла. Ш.к.нең бурычлары — Россиянең Шәрекъ халыклары муз. иҗатын өйрәнү, пропагандалау һәм үстерү, музыка сәнгатенең барлык өлкәләрендә музыка буенча (беренче чиратта милли) кадрлар әзерләү. Барлыгы биш факультет — теория һәм композиция, кыллы һәм тынлы музыка уен кораллары, фортепиано, ялгыз җырлау, музыка-этнография ф-тлары ачыла. Ш.к. каршында фәнни музыка-этнография ассоциациясе эшли, аның әгъзалары татар, мари, чуаш, удмурт, уйгыр һ.б. халыкларның иҗатларын җыю һәм өйрәнү б-н шөгыльләнә. ТАССР ХКСның 1922 ел 11 март карары нигезендә Ш.к. Дәүләт музыка мәктәбе б-н берләштерелә һәм Шәрекъ музыка техникумына үзгәртелә. Ш.к. ТРда беренче тапкыр югары музыка уку йорты төзү омтылышы булып тора. Директорлары — В.М.Айонов, Н.В.Никольский. Әйдәп баручы укытучылары — А.Х.Симаков, Р.А.Гуммерт, В.И.Виноградов, М.А.Пятницкая, О.О.Родзевич, К.А.Корбут, Н.Ф.Катанов, Е.А.Косьмина, А.И.Емельянов һ.б.

**«ШӘРЕ́КЪ КЫЗЫ́»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби хатын-кызлар журналы. Бөтенроссия үзәк мөселман бюросы органы. 1918 елның мартыннан августына кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 6 саны чыга. Мөхәрририяткә Ф.Әмирхан, Г.Гобәйдуллин, Г.Исхакый, Г.Рәхим һ.б. керә. Ф.Бурнаш, Г.Газиз, В.Җәләл, Г.Динмөхәммәтов һ.б.ның әсәрләре басыла. Басманың максаты — кеше хокукларын, гуманизм идеяләрен, хатын-кызларның рухи һәм физик үсешен һ.б.ны пропагандалау. Мөселман татарларның иҗтимагый-сәяси тормышы, аерым алганда, Россия мөселман хатын-кызлары үзәк бюросы эше яктыртыла. Әдәби бүлектә хикәяләр, шигырьләр, сонетлар, балладалар; чит ил язучылары һәм җәмәгать эшлеклеләре, ш.и. Р.Тагор, В.Гюгога багышланган мәкаләләр дөнья кү-




«Шәрекъ кызы» журналы.

рә. Татар әдәбияты (Ф.Әмирханның «Тукай һәм хатын-кызлар»), этнография (Г.С.Сайлуковның «Кыпчак патшалыгының эчке хәлләре тасвирламасы» («Очерк внутреннего состояния Кипчакского царства», басмага Г.Газиз әзерли) буенча материаллар басыла. Гигиена мәсьәләләре (хатын-кызларның тышкы кыяфәтенә, модага зур игътибар бирелә) яктыртыла, балалар тәрбияләү буенча гамәли киңәшләр, кулинария рецептлары басыла.

*З.З.Гыйләҗев.*

**ШӘРЕ́КЪ МАТБАГАСЫ́**, Мәскәүдәге басмаханә. 1917 елда мөселман сәүдәгәрләре пайларына оешкан «*Шәрекъ*» хосусый басмаханәсе җирлегендә барлыкка килә. 1917 дән соң «Шәрекъ матбагасы», соңрак «Кызыл Шәрекъ» дип атала. Шәхси наширләр, оешмалар, газета һәм журнал редакцияләренең заказларын үти. 2 басма машинасы, 250 пот татар һәм 100 пот рус шрифтлары була. Һәр көнне 12 меңгә кадәр басма бит чыгара. Басмаханә штатында 40 тан артык хезмәткәр эшли, мөдире — элекке пайчыларның берсе булган Г.Сәгыйров. 1919 ның гыйнварында РКП(б)ның Мөселман оешмалары үзәк бюросы карамагына тапшырыла. Совет, партия, хәрби оешмалар заказларын үти, иҗтимагый-сәяси, матур әдәбият, уку-укыту ярдәмлекләре бастыра. 1922 дән Үзәк нәшриятның полиграфия базасы була, 1924 тә СССР халыклары үзәк нәшрияты составына керә.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Книги и люди. К., 1985; шул ук. Становление и развитие татарской советской книги. 1917–1932. К., 1989; шул ук. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999.

**ШӘРЕ́КЪ МУ́ЗЫКАСЫ МӘКТӘБЕ́**. 1918–22 елларда Оренбург шәһәрендә эшли. Максаты — татарлар һәм башкортлар арасыннан җырчы һәм музыкантлар әзерләү. Шәкертләре һәм мөгаллимнәре арасында булачак композиторлар С.З.Сәйдәшев, М.М.Вәлиев, музыка белгече Х.И.Булатова-Терегулова һ.б. була.

**«ШӘРЕ́КЪ ОЧКЫНЫ́»**, газета; к. «*Кызыл таң*».

**ШӘРЕ́КЪ ПЕДАГО́ГИКА ИНСТИТУТЫ́**, югары уку йорты. 1922 елда *Казан педагогия институты*, *Шәрекъ академиясе* һәм Казан ун-тының иҗтимагый фәннәр ф-ты җирлегендә булдырыла. Идел-Урал төбәге өчен югары квалификацияле укытучылар һәм мәдәният хезмәткәрләре әзерли. Укыту вакыты — 3–3,5 ел (1929 га кадәр 4 ел). Башта ачылган бүлекләр: тел-тарих, физика-матем., биол.-геогр., шәрекъ телләре. 1924–35 тә бүлекләрнең профиле үзгәрә һәм аларның саны 5 кә кадәр арттырыла: иҗтимагый-икътисади, әдәбият-тел белеме, чуаш, милли лингвистика һәм музей-этнография (1927 дә ябыла). 1927 дә Ш.п.и. составында 8 бүлек эшли: иҗтимагый-икътисади, рус теле һәм әдәбияты, физик-техник, табигыять, татар теле һәм мәдәнияте, чуаш теле һәм мәдәнияте, мари теле һәм мәдәнияте, удмурт теле һәм мәдәнияте бүлекләре. 1930–31 дә читтән торып уку һәм кичке бүлекләр ачыла. Ш.п.и. каршында 2 нче баскыч тәҗрибә-үрнәк мәктәбе эшли. 1930–31 дә милли бүлекләр җирлегендә Чабаксар, Йошкар-Ола, Ижевск шәһәрләрендә пед. ин-тлары ачыла. 1931 дә Ш.п.и. Татар пед. ин-ты итеп үзгәртелә. Ш.п.и.ның барлык эшләгән елларында С.П.Сингалевич ректор була. 1931 гә 139 укытучы, ш.и. 19 проф., 47 фән. канд. эшли. Барлыгы 900 дән артык укучы тәмамлый.

Тикшеренү эшчәнлегенең фәнни юнәлешләре: тарих-филол. (Н.Н.Фирсов, Е.И.Чернышев, М.К.Корбут, Е.Ф.Будде, М.А.Васильев, Г.Ф.Линсцер); табигыять-фәнни (Н.Н.Парфентьев, А.Д.Гольдгаммер, Н.П.Пономарёв); җирле төбәкне өйрәнү: А.Я.Гордягин (Татарстан һәм Чуаш респ-каларының флора һәм геоботаникасы), И.А.Кортиковский (Татарстан һәм Чуаш респ-каларының климатология һәм метеорологиясе), В.Ф. Смолин, Н.С.Надиев, Н.Мөхетдинов, М.Г.Худяков (археол.), В.А.Богородицкий, М.А.Фазлуллин, Г.Х.Алпаров, Г.Ш.Шәрәф, Җ.Вәлиди (тел белеме); Г.Ш.Абдрахманов, Г.Г.Сәгъди (татар әдәбияты тарихы), С.Н.Бикбулатов (ислам һәм татар халкы тарихы), Н.И.Ашмарин (чуаш теле синтаксисы), Н.В.Никольский (чуаш һәм мариларның этнографиясе), В.Г.Егоров (чуаш теле фонетикасы), Г.И.Комиссаров (чуаш фольклоры), С.П.Сингалевич, А.А.Красновский, В.Я.Струминский (пед.).

1924 тән Ш.п.и. каршында Татар пед. җәмгыяте, 1925 тән Рус пед. җәмгыяте эшли, ул басма орган — «Библиографик бюллетень» чыгара. Ш.п.и. басмалары: «Яшь педагог» ж-лы, «Фәнни-педагогик җыентык».

*Әд.:* Новый педагог. Организация и работа Восточного педагогического института в Казани: Итоги пяти лет, 1922–1927. К., 1927; Казанский государственный педагогический институт // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. К., 1974. Вып. 132.

**ШӘРЕ́КЪ ХАЛЫКЛАРЫ́ КОММУНИ́СТИК ОЕШМАЛАРЫНЫ́Ң БЕРЕНЧЕ́ БӨТЕНРОССИ́Я СЪЕЗДЫ́** (Мөселман коммунистларның 1 нче Бөтенроссия съезды), 1918 елның 4–12 ноябрендә Мәскәүдә булып уза. 47 делегат катнаша, аларның 40 гы татар, 1 се башкорт, 2 се әзәрбайҗан, 4 се төрек; 45 ир-ат, 2 хатын-кыз. Казан губернасыннан 17 кеше: Д.Али, А.Богданов, С.Вәлишев, Х.З.Гайнуллин, М.Г.Дулат-Али, М.Г.Конов, Б.Х.Мансуров, К.Нигъмәтуллин, Измаил Рәхмәтуллин, И.Ш.Рәхмәтуллин, Ф.Салихова, М.Субхи, М.Х.Солтангалиев, Г.Г.Таҗетдинова, К.Хәйруллин, Х.Йомагулов, К.Л.Якубов катнаша. Шулай ук Әстерханнан, Мәскәүдән, Түбән Новгородтан, Пензадан, Пермьнән, Петроградтан, Самарадан, Сембердән һәм Тамбовтан делегатлар була. Рәистәшләр: М.Х.Солтангалиев, Г.Ялымов, Н.Яруллин. Съездның көн тәртибе: Мөселман коммунистлар партиясе ҮК доклады; урыннардан докладлар; партия программасы, партия оешмасы һәм Үзәк мөселман комис-тының оештыру мәсьәләләре, Үзәк мөселман комис-ты гыйльми коллегиясе доклады, агымдагы хәлләр, халыкара тактика, сайлаулар. РКП(б) ҮК исеменнән котлау б-н милләтләр эшләре буенча халык комиссары урынбасары С.Пестковский чыгыш ясый; ул, РКП(б) б-н тыгызрак элемтәләр булдыру өчен, съезд партиянең мөселман ҮКн сайлаган иптәшләрнең элеккеге хаталарын кире кагар һәм Мөселман оешмаларының үзәк бюросына керәчәк РКП(б) ҮКна үз вәкилләрен сайлап куяр дигән ышаныч белдерә. Көн тәртибендәге беренче мәсьәлә буенча И.Ш.Рәхмәтуллин чыгыш ясый, ул Мөселман коммунистик оешмасының барлыкка килү тарихына һәм аның РКП(б) б-н мөнәсәбәтләренә туктала. Оештыру мәсьәләләре буенча кискен бәхәс куба. И.Ш.Рәхмәтуллин үзенең чыгышында июньдә Казанда мөстәкыйль ҮК төзелүнең хата булуына һәм съездның, гомуми ҮКка кушылып, аны төзәтергә тиешлегенә басым ясый. Аны К.Л.Якубов яклап чыга, ул барлык коммунистик мөселман оешмалары секция рәвешендә гомуми ком-тларга керергә тиеш дип белдерә. Г.Б.Ашмасов, И.К.Фирдәүс, М.Х.Солтангалиев каршы чыгыш ясыйлар. М.Солтангалиев: «Безнең партия чикләнмәгән. Шуңа күрә без үз ҮКыбызны булдырабыз да... Әгәр ҮК оештыру мөмкин түгел икән, ни өчен Ленин һәм башкалар Россия коммунистлар партиясе ҮКн төзеделәр һәм аны ни сәбәпле дөньяныкы дип атамадылар соң?» — дип белдерә. Озакка сузылган фикер алышулардан соң, съезд күпчелек тавыш б-н, 14 битараф тавыш катнашында, аерым ҮК оештырмаска дигән карар чыгара; *Россия мөселман коммунистлары партиясен* бетерү, *Мөселман коммунистлар комитетларын* мөселман секцияләренә һәм РКП(б)ның җирле ком-тлары каршындагы бюроларга үзгәртү турында карар кабул ителә, РКП(б)ның Мөселман оешмалары үзәк бюросы сайлана; съезд карары буенча аның рәисе итеп И.В.Сталин раслана. Съезд делегатлары Шәрекънең мөселман халыкларына мөрәҗәгать б-н чыгалар, аларны халыкара империализмга каршы күтәрелергә чакыралар. Съездда чыгыш ясаган И.В.Сталин съездның оештыру мәсьәләләре буенча РКП(б) ҮК линиясенә туры килгән карар кабул итүе б-н канәгатьләнүен белдерә.

Чыг.: Первый год пролетарской диктатуры в Татарии: Сб. док. и материалов по истории парторганизации и гражданской войны в 1918 г. К., 1933.

*Әд.:* Хайрутдинов Р.Г. Трудное возрождение. К., 1992.

**ШӘРЕ́КЪ ХАЛЫКЛАРЫ́ КОММУНИ́СТИК ОЕШМАЛАРЫНЫ́Ң ИКЕНЧЕ́ БӨТЕНРОССИ́Я СЪЕЗДЫ́**, 1919 елның 22 октябре — 3 декабрендә Мәскәүдә булып уза. Идел һәм Урал буе, Әзәрбайҗан, Урта Азия, Төньяк Кавказ һ.б. төбәкләрдән 82 делегат катнаша. Татар-Башкорт ССР төзү, хатын-кызлар һәм Шәрекъ яшьләре арасында эш алып бару проблемалары һ.б. тикшерелә. Съездны И.В.Сталин ачып җибәрә, агымдагы хәлләр турында доклад б-н В.И.Ленин чыгыш ясый. Татар-Башкорт Респ-касы турындагы мәсьәлә кискен бәхәс кузгата. РКП(б) ҮК, аны фикер алышуга чыгарып, съездда катнашучыларның тәкъдим ителгән проектны кире кагуына һәм аерым Башкорт һәм Татар Респ-калары төзүне яклавына өметләнә. Әмма күпчелек тавыш б-н Татар-Башкорт ССР турында Нигезләмәне гамәлгә ашыру зарурлыгы хакында карар кабул ителә. *Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы* һәм Татар-Башкорт ССР ревкомының яңа составлары сайлана.

*Әд.:* Г е н к и н а Э.Б. Образование СССР (1917 – 1924). М., 1947; С а й д а ш е в а М.А. Ленин и социалистическое строительство в Татарии. М., 1969; Д а в л е т ш и н Т. Советский Татарстан. Лондон, 1974; Х а й р у т д и н о в Р.Г. Трудное возрождение. К.,1992.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**ШӘРЕ́КЪ ХАЛЫКЛАРЫ́ КОММУНИ́СТИК ОЕШМАЛАРЫНЫ́Ң ҮЗӘ́К БЮРОСЫ́**, РКП(б) ҮК каршында, 1919 елның марты – 1921 нең гыйнвары, РКП(б) Мөселман оешмалары үзәк бюросының дәвамчысы. РКП(б) ҮК бүлеге хокукларында эшли, 1920 нең ноябреннән РКП(б) ҮКның агитация-пропаганда бүлегенә буйсындырыла. Рәисләре: И.В.Сталин, С.Г.Сәетгалиев (1919 ның декабреннән), М.Х.Солтангалиев (1920 дән). Әгъзалары: Б.Сәрдәров, Г.Ялымов, К.Л.Якубов, Х.Й.Йомагулов; Әгъзалыкка кандидатлар: Д.Х.Буниатзаде, М.Г.Дулат-Али, М.Конов, И.Ш.Рәхмәтуллин, Н.Я.Яруллин. Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының 2 нче съездында ҮБның яңа составы сайлана (әгъзалар: Ш.Н.Ибраһимов, М.Бисеров, Б.Х.Мансуров, Н.Н.Нариманов, Х.Г.Раковский, М.Х.Солтангалиев, К.А.Хәкимов; әгъзалыкка кандидатлар: С.М.Диманштейн, А.Мөхетдинов, И.Ш.Рәхмәтуллин, И.К.Фирдәүс, Н.Я.Яруллин). Алга таба ҮБ составы берничә тапкыр үзгәрә. Халыкара пропаганда, нәшрият, мәгълүмат, хатын-кызлар, яшьләр арасында, авылда эшләү буенча бүлекчәләре һ.б. булган оештыру бүлекләре төзелә (зарурияттан чыгып оештырыла). ҮБ мөселман секцияләре һәм бюролары эшен көнчыгыш совет респ-каларында – РКП(б)ның край һәм өлкә бюроларында, респ-каларга кермәгән җирләрдә губерна мөселман бюролары аркылы координацияли (бюролар барлыгы РКП(б)ның 28 край, өлкә һәм губерна ком-тлары каршында эшли), фронтка партия мобилизациясен уздыруда ярдәм итә, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе аркылы Кызыл Армиянең мөселман частьларын оештыруда һәм ныгытуда булышлык күрсәтә. Татар, әзәрбайҗан, фарсы, таҗик, төрек, үзбәк һ.б. телләрдә әдәбият, «Эшче» г-тасын һәм «Кызыл Шәрекъ» ж-лын нәшер итә. 1920 нең ахырына ҮБ секцияләрендә 16 мең кеше, ш.и. 14 мең татар һәм башкорт әгъзалыкта тора. Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының 1 нче Бөтенроссия киңәшмәсе (1921 нең 1 гыйнвары, Мәскәү) карары б-н ҮБ РКП(б) ҮКның агитация-пропаганда бүлеге каршындагы РСФСР төрки халыклары арасында агитация һәм пропаганда үзәк бюросы итеп үзгәртелә.

*Әд.:* Х а й р у т д и н о в Р.Г. Трудное возрождение. К., 1992; Гражданская война и военная интервенция в СССР: Энцикл. М., 1987.

*Л.М.Айнетдинова.*

**«ШӘРЕ́КЪ ХАЛЫКЛАРЫ́ МӘДӘНИЯТЕ́ КҮРГӘЗМӘСЕ́»**, Идел буе, Себер, Иран, Үзәк Азия һәм Кытай халыкларының рәсем һәм гамәли бизәлеш сәнгате әсәрләреннән, кулъязмалар, нумизматика, этнография коллекцияләреннән тупланган вакытлы экспозиция. Казанда Үзәк мөселман фәнни коллегиясе карары б-н ачыла. 1920 елның 28 сентябреннән 1921 нең гыйнвары уртасына кадәр Казан ун-тының геогр. кабинетында эшли. Күргәзмә Казанда Шәрекъ музее оештыру чараларының берсе була. Аны оештыру комиссиясенә Б.Ф.Адлер, Г.С.Гобәйдуллин, П.М.Дульский, Г.Н.Енбаев, П.А.Радимов, М.Г.Худяков, Г.Ш.Шәрәф (соңрак – А.М.Миронов, Н.Ф.Катанов, Б.П.Денике, Б.В.Миллер һәм М.С.Гобәйдуллина) керәләр. Экспозициядә Татарстан респ-касы Үзәк музее, Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыяте, Үзәк шәрекъ китапханәсе тупланмаларыннан, М.Е.Евсевьев, С.М. һәм Г.М.Галиевларның, Г.М.Залкинд, Ф.Аитов, А.М.Миронов, Р.И.Лихачёв һ.б.ның шәхси коллекцияләреннән куелган әсәрләр урнаштырыла. Кытай фарфоры һәм акчалар коллекцияләре Н.Ф.Высоцкийдан, Алтын Урда һәм болгар акчалары Н.Ф.Катановтан, кытай сәнгате әсәрләре С.Е.Маловтан, болгар сәнгате әсәрләре В.С.Смолиннан сатып алына. Күргәзмәдә татар, болгар, нумизматика, китап, Урта Азия, Идел буе һәм Себер халыклары, Кытай бүлекләре була. Эшчәнлегенең беренче аенда анда 10 мең кеше килә. Рус һәм татар телләрендә галимнәрнең күргәзмәнең һәр бүлегенә һәм аның экспонатларына багышланган мәкаләләре кергән юл күрсәткеч басыла. 1920 дә Казанда «Ш.х.м.к.» нигезендә Шәрекъ халыклары музее ачыла. 1921 ел башына кадәр эшли.

*Әд.:* Выставка культуры народов Востока: Путеводитель по выставке. К., 1920.

**«ШӘРЕ́КЪ ЯРЛЫЛАРЫ́»**, газета; к. «*Урал*».

**«ШӘРЕ́КЪ ЯШЬЛӘРЕ́»**, газета; к. «*Яшь коммунар*».

**ШӘРИГА́ТЬ** (гарәпч. شريعت – шәрига – туры, дөрес юл), мөселманның үз-үзен тотышы һәм *Аллаh* ризалыгы өчен тәкъва яшәүдә үтәлергә тиешле шартларның юридик нормалар, принциплар һәм кагыйдәләр комплексы. Ш. кешеләрнең Аллаһка, бер-берсенә мөнәсәбәтләренең төрле формаларын җайга сала һәм аларны үтәмәгән очракта Илаһның җәза дәрәҗәсен аңлата. Ислам тәгълиматы буенча, Ш. принциплары Аллаһ тарафыннан билгеләнгән. Алар *Мөхәммәд* пәйгамбәргә вәхи б-н иңдерелгән. Ш. *Коръәндә*, *Сөннәдә* һәм башка күренекле илаһият галимнәренең хезмәтләрендә бәян ителгән «Илаһи канун» булып исәпләнелә. Ш.не гамәлгә кертү Гарәп хәлифәлегендә 7–12 йөзләрдә формалаша башлый. Аның нигезләмәләре яшәү нормаларын чагылдырган мөселман хокукы – фикъһ өчен чыганак була. Ш. кушканнарны берничә категориягә бүлергә мөмкин: Аллаһка буйсыну б-н бәйле гамәлләр (ш.и. биш тапкыр *намаз* уку, *ураза* тоту, *хаҗ* кылу һ.б.); кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр (сәүдә-икътисад, социаль-мәдәни, гаилә-никах, этика, гигиена һ.б.); хокук бозуларга карата җәза куллану. Ш. буенча мөселман гамәлләре 5 категориягә бүленә: барлык мөселманнар өчен дә фарыз гамәл (мәс., намаз); кирәкле булган (мандуб) – үтәлмәгән очракта җәза бирелми торган яхшы гамәлләр (өстәмә ураза тоту, Коръәнне күчереп язу һ.б.); рөхсәт ителгән (җаиз), әмма макталмый да, хурланмый да торган гамәлләр (ашау, йокы, өйләнү һ.б.); начар күрелгән (мәкруһ) – бу тормышта да, үлгәннән соң да хупланмый, ләкин җәза бирелми торган эш-гамәл (ислам кагыйдәләрен үтәгәндә саксызлык күрсәтү, башка диндәге кеше б-н никах һ.б.); тыелган гамәл (мәхзур) – моның өчен мөселманга бу тормышта да, үлгәч тә җәза бирелә (Аллаһтан башка кемгәдер яки нәрсәгәдер табыну, кеше үтерү, исерткеч куллану, комарлы уеннар уйнау, процентка акча биреп тору һ.б.). Сөннилектә Ш.нең 4 юнәлеше бар: мәлики, хәнбәли, хәнәфи һәм шәфигый. Шигыйләр мәзһәбендә зәедиләр һәм җәфарилар мәктәпләре бар. Хәзерге мөселман Илаһият гыйлеме һәм ислам тәгълиматында Ш. 5 принципка нигезләнгән гомуми канун буларак тәкъдим ителү күзәтелә: гомернең, диннең, гаиләнең, интеллектуаль кыйммәтләрнең һәм мөлкәтнең кагылгысызлыгын саклау. Кайбер мөселман илләрендә (ш.и. Согуд Гарәбстанында, Фарсы култыгы дәүләтләрендә) Ш. законнар кабул итүдә төп чыганак булып тора. Татарстанда татарлар Ш. кагыйдәләрен туганлык мөнәсәбәтләрендә, гаилә-никах, җирләү-искә алу йолаларында һәм кайбер иҗтимагый тормыш аспектларында (к. *Мөселман бәйрәмнәре*) үти.

*Әд.:* С а м а т о в Г.Г. Шәригать: вәгазь, хөкем, фәтва, җавап-сауап, киңәшләр: 3 китапта. К., 2005–06; Ибн Хаджар Аль-Аскалани. Булюг Аль-Марам. Достижение цели в уяснении основ Шариата. М., 2008; Мухаммад-Юсуф Мухаммад-Садик. Права человека в исламе. М., 2008; К е р и м о в Г.М. Шариат: Закон жизни мусульман: ответы Шариата на проблемы современности. СПб., 2009; М а р г и н а н и Б. Хидоя: В 4 т. М., 2010; Z u b a i d a S. Law and power in the Islamic world. N.Y., 2004.

**ШӘРИ́П** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 11 *км* көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 205 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле – кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1758 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.тә мәчет (1835 тән билгеле), җил тегермәне, 2 ярма яргыч, ашлык саклау-сату һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3946,2 дис. тәшкил. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Шәрип (Такталачык) волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан – Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән – Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә – 90, 1834 тә – 217, 1859 да – 395, 1870 тә – 433, 1884 тә – 494, 1897 дә – 521, 1906 да – 602, 1913 тә – 500, 1920 дә – 383, 1926 да – 410, 1938 дә – 458, 1949 да – 388, 1958 дә – 403, 1970 тә – 399, 1979 да – 340, 1989 да – 244, 2002 дә – 213 кеше.

**ШӘРИ́ПОВ** Әлимҗан Йосыф улы (20.6.1930, Ульянов өлкәсе), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1980), проф. (1982). 1960 елда Бөтенсоюз финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1968–72 дә Новосибирск югары хәрби-сәяси уч-щесендә укыта, 1972–93 тә икътисад каф. мөдире, Халык хуҗалыгы ин-ты проректоры (Новосибирск ш.). Хезмәт күрсәтү өлкәсендәге проблемаларга, төбәк систе-



Н.Х. Шәрипов.

маларына фаразлау һәм планлаштыруга караган хезмәтләр авторы. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сфера услуг Сибирского региона. Новосиб., 1979; Социальная инфраструктура в концепции ускорения. Новосиб., 1990.

**ШӘРИ́ПОВ** Әнвәр Мәгъдәнур улы (9.10.1941, Ютазы р-ны Кәрәкәшле а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2002), проф. (2005), шагыйрь. ТРның атказ. укытучысы (2005). РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2013). Казан ун-тын тәмамлый (1965). 1971 елдан РФА КГҮнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1978 дән Алабуга пед. ин-тында, 1990 нан (бүленеп), Чаллы пед. ин-тында (2001–08 дә татар әдәбияты һәм аны укыту методикасы каф. мөдире). Хезмәтләре урта гасырлар төрки-татар әдәбиятына, урта мәктәптә һәм югары уку йортларында аны укыту методикасына, чыганакларны өйрәнүгә, урта гасырлар төрки-татар әдәбиятының Шәрекъ әдәбиятлары б-н үзара бәйләнешләренә багышлана. Г.Утыз Имәни, Кол Шәриф, Сирин әсәрләренең кульязмаларын беренче тапкыр текстологик өйрәнеп бастырып чыгара (Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари. «Шигырьләр, поэмалар», 1986; Кол Шәриф. «И күңел, бу дөньядыр... Газәлләр, кыйсса», 1997). «Кем иден син?» (2006), «Тукта, мизгел!» (2013) шигырь җыентыклары авторы. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Борынгы татар әдәбиятының авыр үзләштерелә торган мәсьәләләре. Яр Чаллы, 2008; Орхон-Енисей язмалары // Татар әдәбияты тарихы. Т. 1. Борынгы чор һәм Урта гасырлар. К., 2014; Борынгы уйгур язулы истәлекләр // Татар әдәбияты тарихы. Т. 1. Борынгы чор һәм Урта гасырлар. К., 2014; Габдерәхим Утыз Имәни // Татар әдәбияты тарихы. Т. 2. XV–XVIII гасырлар. 2014; Зарождение системы стихотворных жанров в древнетюркской и тюрко-татарской литературе (VIII–XIV вв.). К., 2001; Литература народов Поволжья и Приуралья. Ч. 1. Татарская литература: история и современность. Наб. Челны; 2018.

*Әд.:* Б а к и р о в М. Заман күзлегеннән карап? // Казан утлары. 1987. № 10; Ш ә р и п о в а Л. Әнвәр Шәриповның фәнни-тәнкыйди һәм әдәби эшчәнлеге. К., 2011; С а л и м з я н о в а Э.Ш. Анвар Шарипов: научный и литературный портрет писателя. К., 2016.

**ШӘРИ́ПОВ** Вил Вилдан улы (28.5.1947, Оренбург өлкәсенең Саракташ р-ны Рәдүт (Никитино) а. – 19.12.2011, Одесса ш.), генерал-майор (1997). Саратов югары командир-инженерлар уч-щесен (1970), М.И.Калинин исем. Хәрби артиллерия академиясен (Ленинград, 1980) тәмамлый. 1970–91 елларда СССР Кораллы Көчләрендә: 1970 тән Урта Азия хәрби округы (Казакъстан) артиллерия дивизиясенең техник батареясы командиры, 1980 нән Одесса хәрби округы (Симферополь ш.) корпусының артиллерия коралландыру хезмәте башлыгы, 1986 дан Ерак Көнчыгыш хәрби округының (Петропавловск-Камчатский ш., Көньяк Сахалин ш.) 51 нче гомумгаскәри армиясендә 25 нче армия округының ракета-артиллерия коралландыру хезмәте башлыгы. 1991 дән Украина Кораллы Көчләрендә: 1993 тән Көньяк оператив командованиенең (Симферополь ш.) ракета-артиллерия коралландыру хезмәте башлыгы. 2000–05 тә Одесса коры җир гаскәрләре ин-тында эшли. 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ШӘРИ́ПОВ** Дөлфәт Шәриф улы (22.5.1939, Актаныш р-ны Югары Яхшый а.), патофизиолог, вет. фән. д-ры (1989), проф. (1993), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (1999). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1965). Удмурт АССРның Грахово р-ны «Граховский» с-зында вет. табибе булып эшли. 1967–2007 елларда (бүленеп), Казан вет. медицинасы академиясендә, патофизиология каф. мөдире (1992 дән). 1979- 92 дә Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан) патоморфология лаб-ясе өлкән фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре матдәләр алмашы бозылу б-н бәйле авырулар патогенезы һәм патоморфологиясен, яшь а.х. терлекләрендә респиратор авыруларны, терлекләрнең агулану очракларын, яңа дезинфектантлар һәм мөгезле эре терлекләр хламидиозына каршы вакцинаның нәтиҗәлелеге һәм зыянсызлыгы мәсьәләләрен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: О токсической дистрофии печени поросят // Ветеринария. 1972. № 10; Медленные инфекции овец: результаты клинико-эпизоотологических, серологических и патоморфологических исследований // Уч. зап. Казан. академии вет. медицины. 2002. Т. 172 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

**ШӘРИ́ПОВ** Илгизәр Ибраһим улы (11.1. 1960, Әлки р-ны Аппак а.), агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). Тәтеш совхоз-техникумын тәмамлый (1982). Әлки р-ның «Дружба» к-зында рәис урынбасары (1982 елдан), агроном (1985 тән), баш агроном (1991 дән) булып эшли. Дәүләт бүләге ТРда үләнчел сорго орлыкчылыгын оештыру, үстерү, куллану технологияләрен эшләүдә һәм аны җитештерүгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ШӘРИ́ПОВ** Марат Сабит улы (26.3.1962, БРның Чишмә р-ны Иске Муса а.), җырчы (бас), БРның атказ. артисты (2009), ТРның халык артисты (2010), филол. фән. канд. (1988). Башкорт ун-тын (1984), Уфа сәнгать ин-тын (Р.Г.Галимуллинада ялгыз җырлау классы) тәмамлый. 2001 елдан Башкорт опера һәм балет театры солисты. Бер үк вакытта, 1988 дән, Башкорт ун-тының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасында укыта. Төп партияләре: Цунига, Эскамильо («Кармен», Ж.Бизе), Феррандо, Рамфис, Монтероне («Трубадур», «Аида», «Риголетто», Дж.Верди), Бонза, Анджелотти («Мадам Баттерфляй», «Тоска», Дж.Пуччини), Бертран («Иоланта», П.Чайковский), Суык бабай («Кар кызы», Н.Римский-Корсаков), Төхбәт, Иван Грозный («Урал илчеләре», З.Исмәгыйлев) һ.б. С.Сәйдәшев исем. Бөтенроссия вокалистлар конкурсында Гран-при лауреаты (1991), Ю.Гуляев исем. Бөтенроссия опера җырчылары (1993), Халыкара «Татар җыры-95» конкурслары лауреаты. Җәмәгать эшчәнлегендә актив катнаша: Башкортстан Респ-касы Президенты каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы, «Рамазан» төрки милли-агарту үзәге рәисе (Уфа).

**ШӘРИ́ПОВ** Нурми (Нурмөхәммәт) Хәләф улы (15.2.1925, Чаллы кантоны Казаклар а. – 21.7.1944, Украина, Львов өлкәсе, Каменка-Буг р-ны, Банюнин авылында җирләнә, соңрак җәсәде Львов шәһәренә күчерелә), Сов.Союзы Герое (23.9.1944, үлгәннән соң), гв. сержанты. Туган авылында колхозда эшли. 1943 елның февраленнән Кызыл Армиядә. 1943 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 53 нче гв. танк бригадасының разведка взводы отделениесе командиры (3 нче гв. танк армиясенең 6 нчы гв. танк корпусы). Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Житомир-Бердичев (1943–44), Проскурово-Черновцы һәм Львов-Сандомир (икесе дә — 1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 21 июлендә Львов шәһәре өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: Кукезов авылы янында беренче булып дошман траншеясына бәреп керә, пулемёт расчётын юк итә һәм офицерны әсирлеккә ала. Разведка төркеме «тел» б-н чигенгәндә ике аягы да яралана. Иптәшләрен ышыклап, соңгы патронына кадәр пулемёттан ата, аннан соң үзен һәм аны чолгап алган дошманнарны граната б-н шартлата. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медаль б-н бүләкләнә. Тукай р-ның Теләнче Тамак мәктәбе янында Геройга һәйкәл куелган, туган авылындагы бер урамга аның исеме бирелгән.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*Р.Р.Сәләхиев.*

**ШӘРИ́ПОВ** Раушан Тимерҗан улы (Раушан Шәриф) (27.10.1963, БРның Туймазы р-ны Татар Олканы а.), драма актёры, педагог, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2008). Мәскәүдә М.С.Щепкин исем. Югары театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1988), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Игътибарны җәлеп итәрлек характерлы рольләр остасы, темпераментлы һәм мөлаем актёр. Аеруча зур рольләре: Корышкан («Җәһәннәм биюе», К.Хоинский), Хәйрүш («Ат карагы», Т.Миңнуллин), Бенволио («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир), Фирдәвес, Хәмзә («Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре», «Баскетболист», М.Гыйләҗев), Рәшит («Килә ява, килә ява», «Ява карлар, ява карлар», З.Хәким), Арсен («Тол ханымда тукталыш», Э.Лабиш). 2008 елда Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында (хәзер Казан мәдәният ин-ты) укыту эшенә күчә, ш.у. әдәби эшчәнлек б-н дә шөгыльләнә.

*Әд.:* И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.
*И.И.Илялова.*

**ШӘРИ́ПОВ** Рәниф (30.5.1950, Кукмара р-ны Аман Оштырма а.), шагыйрь, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2006). Казан химия-технол. ин-тында укый (1967–68). Шигырьләрендә («Тәрәзәдәге утлар» (1983), «Күк һәм күңел йолдызлары» (1989), «Мәңгелек сер» (2005) җыентыклары) һәм поэмаларында («Чокырча тавы»; «Алмагачлар сагышы» икесе дә — 1983; «Бакча», «Фатыйма мәхәббәте», икесе дә — 1989; «Йорт иясе», 1996; «Зәйтүнә мәхәббәте», «Азатлык», икесе дә — 2008 һ.б.) Ш. кешенең җирдәге урыны, җәмгыять тормышында аның роле, әхлак мәсьәләләре турында уйлана. Балалар өчен «Ян, учагым!» (1988) китабы авторы.

Ә с ә р.: Азатлык көне. К., 2012.

*Әд.:* Учагың сүрелмәсен // Вәлиев М. Әйтер сүзең булса. К., 1988.

**ШӘРИ́ПОВ** Сабир Шәриф улы (25.10.1882, Вятка губ., Алабуга өязе Барҗы а. — 17.7.1942, Казакъстан ССР), хакимият-хуҗалык, җәмәгать эшлеклесе. А.х. мәктәп-интернатын тәмамлый (Семипалатинск өлкәсенең Павлодар ш., 1903). Урта Азиядәге 1916 елгы баш күтәрүдә һәм Себердә, Төркестанда, Казакъстанда (Күкчәтау, Павлодар шәһәрләре) Совет хакимиятен урнаштыруда катнаша. 1919 да Омск губернасының Атбасар өязе хезмәт комиссары, башкарма ком-ты рәисе. 1920 дән Акмулла губернасы (Казакъстан) революцион ком-ты әгъзасы, башкарма ком-ты рәисе. 1924–32 дә Эмба промыселы (Казакъстан) идарәчесе, «Эмбанефть» тресты (Мәскәү) идарәсе рәисенең урынбасары; Совет-Иран «Вевир-Хуриан Лиматед» АҖнең директор-инспекторы (1932–34), Көньяк Казакъстанда СССР Тышкы сәүдә халык комис-ты вәкиле. 1935–37 дә Казакъстан КП ҮК каршындагы Партия тарихы ин-тының өлкән фәнни хезмәткәре. 1937 дән «Эмбанефть» тресты Эмба нефть промыселы һәм геол. разведкасының Доссор тирән скважинасы конторасы мөдире. «Алтыбасар» (1926), «Рузи Иран», «Канунсызлык» (икесе дә — 1935), «Ләйлә» (1937) повестьлары, «Баш күтәрү алдыннан», «Массакүләм баш күтәрү», «Алабас» (барысы да — 1936), «Улкейек ярында», «Тайшим Орысулы» (икесе дә — 1937) очерклары, «Шәһәргә чыгу», «Ерден күле» (икесе дә — 1929), «Камен» (1935), «Жаубасар» (1936) хикәяләре һ.б. авторы. «Бикбулат» повесте чынлыкта булган вакыйгаларга нигезләнә: Бикболатның прототибы — Тургай даласында рус колонизаторларына каршы кузгалган казакъ милли азатлык күтәрелешенең юлбашчысы казакъ милли каһарманы Амангилде Иманов. 1941 дә репрессияләнә һәм атып үтерелә; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Н у р г а л и е в Р.Н. Сабыр Шарипов. А.-А., 1961; Казахская ССР: Краткая энцикл. А.-А., 1991; Алматы: Энцикл. Алматы, 1996.

**ШӘРИ́ПОВ** Сәлимҗан Әхтәм улы (1.1.1945, Балык Бистәсе р-ны Таулар а.), галим агроном, икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1996), РАХФА, ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2010, 2011), РФнең, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995, 2002), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2006). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1974). 1967–76 елларда Балык Бистәсе р-нында: ДОСААФ район ком-ты рәисе, 1970 тән ВЛКСМ район ком-тының 1 нче секретаре, 1974 тән «Россия» к-зы рәисе. 1976–79 да ТАССР А.х. министрлыгында: орлыкчылык бүлеге башлыгы, «Татарсортсемпром» берләшмәсендә баш агроном. 1979–81, 1984–88 дә «Татарстан кыры» ФҖБнең орлыкчылык, 1988–95 тә планлаштыру, координацияләү һәм пропаганда бүлекләре мөдире. 1981–84 тә КПСС өлкә ком-тының а.х. мелиорациясе секторы мөдире. 1995 тән Татарстан агробизнес кадрларының белемен күтәрү ин-ты ректоры, 2013 тән проректор, проф. (1999). Төп хезмәтләре Татарстанда аграр пр-тиеләрне урнаштыру, орлык җитештерүне оештыру, агросәнәгать комплексында идарәче хезмәткәрләрнең эшен бәяләү һәм хезмәтчәннәрне социаль-хокукый яклау мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Семеноводство на промышленную основу. К., 1980; Климат, земля, урожай. К., 1995; Концепция кадровой политики в АПК Республики Татарстан: Механизм и программа её реализации. К., 1999; Состояние производства и пути повышения качества зерна в Республике Татарстан. К., 2000; Состояние и концепции развития зернового хозяйства и рынка зерна. К., 2009.
*Ф.С.Зыятдинов.*

**ШӘРИ́ПОВ** Урал Зыятдин улы (6.5.1937, Ленинград), тарихчы, икътисадчы, икътисад фән. канд. (1965), тарих фән. д-ры (1999). Ташкент ун-тын тәмамлый (1961). 1965–66 елларда шунда ук укыта. 1966–68 дә СССРның Әфганстандагы Сәүдә вәкиллегендә (Кабул) икътисадчы. 1969 дан СССР ФАнең (РФА) Көнчыгышны өйрәнү ин-тында халыкара мөнәсәбәтләрнең комплекслы проблемалары бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, бер үк вакытта Мәскәү автомобиль юллары төзү ин-тында, Мәскәү пед. ун-тында һәм Россия Халыклар дуслыгы ун-тында укыта. Хезмәтләре Якын һәм Урта Көнчыгышның икътисади һәм халыкара мөнәсәбәтләренә карый. Р.М.Шәрипова б-н берлектә Коръәнне гарәп теленнән рус теленә тәрҗемә итә (2009). Мәскәү татар иҗтимагый үзәге советы (1991–2002), Мәскәүнең Милли җәмгыятьләр ассоциациясе (1995–2000) рәисе.

Х е з м.: Бюджет и бюджетная система Ирана. М., 1976; Политика и нефть в Персидском заливе в 70–80-е годы. М., 1994; Россия, Ближнее и Дальнее зарубежье Азии. М., 1997 (автордаш); Персидский залив: обострение политической и военной ситуации и международных отношений в конце XX — начале XXI вв. М., 2010.
*Ф.С.Зыятдинов.*

**ШӘРИ́ПОВ** Фатыйх Зариф улы (20.1.1921, Бөгелмә кантоны Бәйрәкәтамак а. — 4.6.1996, С.-Петербург), Сов. Союзы Герое (10.1.1944), подполковник. Бөгелмә пед. уч-щесен (1937), Казан танк уч-щесен (1942), Ленинград бронетанк һәм механикалаштырылган гаскәрләр югары мәктәбен (1946) тәмамлый. 1937–40 елларда урта мәктәптә укытучы булып эшли. 1942 нең маеннан Кызыл Армиядә һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында, 183 нче танк бригадасының танк ротасы командиры (40 нчы армиянең 10 нчы танк корпусы). Брянск, Воронеж, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Воронеж-Касторное, Белгород-Харьков һөҗүм операцияләрендә, Днепр елгасы өчен сугышта (барысы да — 1943), Яссы-Кишинёв (1944) һәм Братислава-Брно (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең 23 сентябрь төнендә Балык авылы янында (Украина ССРның Киев өлкәсе Кагарлык р-ны) Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: Ш. җитәкчелегендәге моторлаштырылган рота елга аша кичеп, сугышып плацдарм яулый; өч тәүлек дәвамында дошман контрһөҗүмнәрен батырларча кире кайтара. 1951 дә отставкага чыга, Ленинград диңгез уч-щесендә эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Баулы шәһәрендә сугышта һәлак булганнар истәлегенә Мәңгелек ут кабызылган һәм Баулы, Ютазы р-ннарында туган Сов. Союзы Геройлары (ш.и. Ш.) бюстлары урнаштырылган мемориаль комплекс төзелгән. Казанның Җиңү паркындагы мемориаль комплекста Ш. исеме язылган мәрмәр такта куелган.



Ф.З.Шәрипов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.
*М.З.Хәбибуллин.*

**ШӘРИ́ПОВ** Фәнис Вагыйзь улы (20.9.1941, БАССРның Бүздәк р-ны Сабай а.), педагог, пед. фән. д-ры (1997), проф.(2001). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1967). 1974 елдан Уфа авиация-техник ун-тының социол. һәм политология кафедрасында, бер үк вакытта, 1999 дан, Уфа эшмәкәрлек һәм хокук техникумы директоры. Хезмәтләре югары мәктәптә белем бирү процессы алымнарына һәм эчтәлегенә, психол. мәсьәләләренә карый. БРның мәгариф отличнигы (2001), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2002).

Х е з м.: Моделирование личности и деятельности специалиста. М., 1984; Психология менеджмента. Уфа, 2004; Психология и педагогика. Уфа, 2006; Педагогика высшей школы. Уфа, 2008; Психологические основы менеджмента. М., 2008.

**ШӘРИ́ПОВ** Хәмзә Мәүлихан улы (4.2.1957, Пермь өлкәсенең Барда р-ны Аклыш а.), нәкышьче, график, гамәли-бизәлеш сәнгате остасы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2007). В.И.Мухина исем. С.-Петербург сәнгать-сәнәгать академиясен тәмамлый (1987). 1988 елдан Чаллы шәһәрендә. 1991 дән Татарстан рәссамнары берләшмәсенең Чаллы ф-лында (1995–97 дә рәис). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1996). «Тамга» рәссамнар төркемен оештыручыларның һәм иҗат лидерларын-

нан берсе (2000), «Европа-Азия» халыкара гуманитар академиясенең мактаулы әгъзасы (2006).

Ш. иҗат юлын гобелен, ефәк б-н эшләүче буларак башлый, әкренләп сынлы сәнгатьнең башка төрләрендә дә үзен күрсәтә. Татар халкының орнаменталь мирасы (чигү, каюлы күн, туку) уңышлы чагылдырылган гобелен техникасында декоратив «Төш» панносы (1984), «Салават күпере» (1989), «Авыл пейзажы» (1987), «Бәйрәмчә киенгән урман» (1990), «Гөлбакча» (1992), «Безнең чәчәкләр бәйрәме» (1994) батик паннолары, «Шахмат клубы» батик пәрдәсе (1989) һ.б. авторы.

1990 еллар башыннан Ш. халык традицияләрен үстерә барып станлы нәкышькә һәм графикага, җыр фольклорына, гамәли-бизәлеш сәнгатенә мөрәҗәгать итә. Үзенең әсәрләрендә коллаж принцибында төрле техникаларны берләштерә, абстракт сәнгать классикларыннан (аерым алганда, П. Мондрианнан) өземтәләр китерә, төгәл геом. композиция корылышын татар орнаменты калыплары б-н үреп бара, бу аның иҗатын постмодерн сәнгате б-н якынайта. Ш.ның образлар дөньясы чыганагы төрки-татар мифологиясенең архаик катламнарына барып тоташа. Станлы нәкышь һәм бизәлеш сәнгате чикләрендә иҗат ителгән картиналары фәзаи шартлылык, тамга һәм символлар киң кулланылу б-н аерылып тора. Ш.ның сурәтләү теленә ачык локаль төсләрнең үзара ярашуы, калыпларның төгәл график модельләшүе хас. Киндернең махсус эшкәртелми калдырылган өлешләре тукыны, чигүне, тукымадагы аппликацияләрне хәтерләтә. Картиналар композициясенә кертелгән текст (татар халык җырларыннан юллар, Коръән сүрәләре) заманча нәкышь үрнәкләрен шәмаилләргә хас ысуллар, татар фольклоры поэтик образлары б-н баета.

«Җыр» (1993), «Истәлекләр» (1994), «Ак бүре», «Җир-юрган», «Чишмә» (барысы да — 1995), «Сак-Сок», «Мондрианга юллама», «Мәҗүси» (барысы да — 1996), «Җир һәм Күкнең үбешүе» (1998), «Борынгылар авазы», «Онытылган көй» (икесе дә — 2001), «Алабугада айлы төн» (2006), «Җир рухы», «Вакыт көпчәге», «Бабалар» (барысы да — 2008), «Айлы күк астында», «Удмурт урманы» (икесе дә — 2010), «Шүрәле кош белән» (2011) картиналары авторы. Кайбер картиналары (пейзажлар, натюрмортлар) реалистик манерада эшләнгән: «Җәйге кич» (1994), «Болгардагы көнчыгыш төрбә», «Натюрморт», «Төркиядәге таулар», «Анталиягә юл», «Гюреме. Каппадокия», «Таулардагы күл» (барысы да — 1999), «Аклыш авылы» (2000) һ.б. Графика әсәрләре башлыча пастель техникасында башкарыла: «Кәккүк тавышы», «Айлы төн» (икесе дә — 1998), «Болгарлар җире» (2001) һ.б. Гобелен «Агач» (2002), салкын һәм кайнар батик техникаларында — «Алтын балык» (2010) паннолары ясый. Тукыма интарсиялар авторы: «Очу теләге» (1999), «Ерактагы чакыру авазы» (2005), «Күк юлы» (2007) һ.б. 2010 еллардан эмаль техникасын үзләштерә, «Үләндәге кош», «Төнлә», «Зөһрә», «Күчмән», «Чәчәк атучы агач» (барысы да — 2011) панноларын иҗат итә.

1989 дан башлап респ-ка — 2 нче респ-ка гамәли-бизәлеш сәнгате (Казан, 1989); Әбу-Дабида Татарстан рәссамнары (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре,1994); төбәкара — «Зур Идел» (1998, 2000, 2010); бөтенроссия — «Классика һәм хәзерге заман» (2000), «Россия-11» (2009) (икесе дә — Мәскәү); халыкара — Ислам илләренең 1 нче бөтендөнья фестивалендә (Исламабад, Пакъстан, 1994), «Ике автошәһәр» (Париж, Франция, 1995), «Төрки дөнья» (Әнкара, Төркия, 1998, 2002) күргәзмәләрендә, «Камва» этнофестивалендә (Пермь, 2007–09), заманча төрки сәнгать биенналесендә (Акшәһәр ш., Төркия, 2010) катнаша. Шәхси күргәзмәләре 2015 тә (Уфа), 2017 дә (Казан) уздырыла. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, төрле илләрдәге шәхси тупланмаларда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, «Туран» фондында (Казан), Төркия, Венгрия, Германия, АКШ, Япониядә саклана. «Ел рәссамы» бүләге лауреаты (2003), 3 нче халыкара «Дөнья көзгесе» эмаль биенналесе призёры (С.-Петербург, 2017).

*Әд.:* С у л т а н о в а Р.Р. Искусство новых городов Республики Татарстан (1960–1990). К., 2001; Н и г м а т у л л и н а Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002; Ч е р в о н н а я С.М. Современное исламское искусство народов России. М., 2008. *Г.Р. Фәйзрахманова.*

**ШӘРИ́ПОВА** Венера Гәрәй кызы (27.12. 1927, Үзбәкстан ССР, Бохара өлкәсенең Шерабад пос. — 9.12.1989, Казан), җырчы (лирик-колоратуралы сопрано), ТАССРның һәм РСФСРның халык артисты (1964, 1970). 1950 елда Мәскәү консерваториясен (Е.Торшилова-Серебровская классы) тәмамлый. 1950–72 дә Татар опера һәм балет театрының әйдәп баручы солисты (Ш.Гунонының


В.Г. Шәрипова.

«Фауст» операсында Маргарита партиясе б-н беренче тапкыр чыгыш ясый). Төп партияләре: Леонора, Виолетта («Трубадур», «Травиата», Дж. Верди), Ләйлә («Энҗе эзләүчеләр», Ж.Бизе), Чио-Чио-сан («Мадам Баттерфляй», Дж. Пуччини), Татьяна, Иоланта («Евгений Онегин», «Иоланта», П.Чайковский), Алтынчәч (шул исем. әсәр буенча, Н.Җиһанов), Сәрвәр («Башмагым», Җ. Фәйзи) һ.б.


В.Г. Ш ә р и п о в а: 1. Адель («Яркканат», И.Штраус; Фальк ролендә – А.Матеосов); 2. Форд ханым («Виндзор шәһәренең шаян ханымнары», О.Николаи; Педж ханым ролендә – Н.П.Зайцева, Фальстав – Л.С.Верниковский) рольләрендә.


Х.М. Ш ә р и п о в. 1. «Хәбәр». 1995; 2. «Түгәрәк күл». 1995; 3. «Мондрианга юллама». 1996; 4. «Кадерле моңнар». Драп. Интарсия. 2011.

Шулай ук оперетталарда да баш рольләрне башкара. 1972–89 да Татар филармониясе солисты. Ш.ның концерт репертуарын чит ил, рус, татар композиторларының камера-вокаль әсәрләре тәшкил итә. Матур тышкы кыяфәткә, сыгылмалы, барлык регистрларда да тигез яңгырашлы, йомшак тембрлы тавышка ия.

*Әд.:* В а н с л о в В. Торжество ума и сердца // Театральная жизнь. 1963. № 13; К у л и к о в В. Завидное долголетие // Театральная жизнь. 1964. № 6.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ШӘРИ́ПОВА** Гайшә Габделхәмит кызы (12.9.1901, Казан — 7.7.1969, Алма-Ата), язучы, тәрҗемәче. Рус телендә яза. 1936 елдан Алма-Атада яши, Казакъстан дәүләт нәшриятында мөхәррир, тәрҗемәче булып эшли. «Җиде диңгез аша» («Через семь морей», А.-А., 1958), «Ал канатлар» («Алые крылья», А.-А., 1969) повестьлары, «Гафур гаиләсе» («Семья Гафура», А.-А., 1969) романы авторы. Казакъ (М.Ауэзов, С.Сәйфуллин, С.Муканов һ.б.) һәм татар авторларының (Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» — «Дочь степи», «Татар хатыны нилӛр күрми» — «Татарка», «Тирән тамырлар» — «Глубокие корни», К.Нәҗми хикәяләре) әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* И с х а к о в Б. Казак-татар әдеби байланысы. А.-А., 1976.

**ШӘРИ́ПОВА** Маргарита Рәшит кызы (27.6.1956, Магадан өлкәсенең Эгвекинот пос.), микробиолог, биол. фән. д-ры (2001), проф. (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1978), шунда ук эшли. Хезмәтләре микроорганизмнар ферментларына, аларның синтезы һәм эшләү механизмнарына карый. Ш. бактерияле гидролазалар алу ысулын эшли, аларның вируска һәм фагиягә каршы активлыгын билгели. Уйлап табуга 5 патенты бар. «Bacillus intermedius рибонуклеазасы. Биосинтез һәм биотехнология» («Рибонуклеаза Bacillus intermedius. Биосинтез и биотехнология») дигән хезмәтләр циклы өчен СССР ФА югары уку йортларының яшь галимнәре дипломына (1988); «Потенциаль терапия препараты буларак микроорганизмнар гидролазалары» хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләгенә (2008) лаек була.

Х е з м.: Поздние стадии секреции белков у бацилл (обзор) // Биохимия. 2002. Т. 67, вып. 11; Выделение и характеристика глутамилэндопептидазы B. intermedius, секретируемой рекомбинантным штаммом B. subtilis на разных фазах роста // Биоорганическая химия. 2008. Т. 34, № 3 (автордаш); Биохимические свойства субтилизиноподобной протеиназы B. intermedius, секретируемой рекомбинантным штаммом B. subtilis в стационарной фазе роста // Биохимия. 2009. Т. 74, вып. 3 (автордаш).

**ШӘРИФҖА́НОВ** Исмәгыйль (Измаил) Ибраһим улы (23.6.1940, Башкортстан АССРның Ишембай ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1990), проф. (1992), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1997, 2009). Томск ун-тын тәмамлаганнан соң (1964), шунда ук эшли. 1969–79, 1980–87 елларда Казан пед. ин-тында. 1979–80 дә Матансан шәһәрендәге (Куба) Югары пед. ин-тының укытучы-консультанты. 1987 дән Казан ун-тында, яңа һәм иң яңа тарих (1991–2010) каф. мөдире. Хезмәтләре гомуми тарихка багышлана. Ш. илдә чит илләр новистикасын үстерүгә, Бөекбритания, Польша һ.б. илләрнең тарихын һәм историографиясен тикшерүгә җитди өлеш кертә. 1999 дан «Clio moderna. Зарубежная история и историография» еллык басмасының баш мөхәррире. Парламент һәм сайланган оешмалар тарихы буенча халыкара комиссиянең (Лондон, Англия, 1991 дән), Россия һәм Польша тарихчылары комиссиясе (1992 дән), ЮНЕСКОның мәктәп дәреслекләре буенча комиссиясе (Брауншвейг, Германия, 1997 дән) әгъзасы.

Х е з м.: Судьбы либеральной философии истории: Актон и современная англо-американская историография. К., 1989; Польские профессора и преподаватели в Императорском Казанском униврситете. К., 2002; Английская историография в XX в.: Основные теоретико-методологические тенденции, школы и направления. К., 2004.

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999; Британская ойкумена Российской новистики (к 70-летию профессора И.И. Шарифжанова). К., 2010.

*Ф.Г. Миңнеханов.*

**ШӘРИФИ́** Гариф (Мөхәммәтгариф) Ибраһим улы (19 йөз ахыры — 20 йөз башы), шагыйрь. Мәдрәсәләрдә укыта (Чистай ш. һәм Яуширмә а.). Ш. шигырьләрендә («Вакыт», «Идел» г-таларында, «Аң», «Шура» һ.б. ж-лларда басылганнар) татар милләтенең язмышы турында борчулы уйланулары чагыла. Милләтнең үсешен һәм чәчәк атуын Ш. Россиядәге иҗтимагый стройның үзгәрүе б-н бәйли. «Идеал, яки күңел теләге» (1912), «Күңел зары» (1913) җыентыклары, пед. буенча мәкаләләр авторы.

*Әд.:* Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004.

**ШӘРИФУ́ЛЛИН** Вилен Насиб улы (1.1.1944, Сарман р-ны Теләнче Тамак а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1995), проф. (1997). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), Куйбышев азот-тук з-дында эшли. 1969 елдан Мәскәү химия-технол. ин-тында, 1972 дән Бөтенсоюз агач эшкәртү сәнәгате фәнни-тикшеренү ин-тында (Балабаново ш.). 1973–95 тә Казан химия-технол. ун-тында, 1995 тән Казан энергетика ун-тының инженерлык кибернетикасы каф. мөдире. Хезмәтләре химик-технол. процесслар кибернетикасына карый. Ш. газ-сыекча системасындагы масса тапшыруга өслекчә-актив матдәләр йогынтысын тикшерә. Ферментация процессларының (төп кормалар аппаратларындагы) матем. модельләрен, ш.у. ташландык суларны биохимик чистарту системаларын эшли. Органик синтез технологиясендә химик матдәләр б-н пычранган суларны һәм һавага чыккан газларны арындыру ысулларын тәкъдим итә. Фәнни эшчәнлек нәтиҗәләре «Казаноргсинтез» АҖдә, Светлобоярск биохимия з-дында, Кстов биовитамин комб-тында һ.б.да гамәлгә кертелә.

Х е з м.: Моделирование и оптимизация системы биоочистки стоков // Биотехнология. 1999. № 5 (автордаш); Массопередача в присутствии поверхностно-активных веществ // Теорет. основы хим. технологии. 2002. № 3 (автордаш).



Д.Г.Шәрифуллин.



З.Г.Шәрифуллин.

**ШӘРИФУ́ЛЛИН** Даһи Гарифулла улы (15.7. 1928, Бөгелмә кантоны, хәзер Лениногорск р-ны Зәй-Каратай а. — 20.1.2003, шунда ук), механизатор, Соц. Хезмәт Герое (1966). Бөгелмә а.х.н механикалаштыру мәктәбен тәмамлый (1952). 1943–99 елларда Лениногорск р-ның «Уңыш» к-зында эшли: комбайнчы (1952 дән), комплекслы бригада бригадиры ярдәмчесе (1966 дан). Бөртекле культуралар чәчү һәм уңыш җыю эшләрендә комбайнчыларның катнашуын башлап җибәрүче. Бөртекләләрне суктырганда техникадан рациональ файдаланып, рекордлы җитештерүчәнлеккә ирешә. Герой исеме бөртекләләр һәм терлек азыгы культураларын җитештерү һәм әзерләүне арттыруда һәм техникадан югары җитештерүчән файдалануда ирешелгән уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШӘРИФУ́ЛЛИН** Зиннәт Галиулла улы (15.10.1916, Самара губ., Бөгелмә өязе, хәзер Лениногорск р-ны Шөгер а. — 4.1.2010, шунда ук), нефть чыгару операторы, Соц. Хезмәт Герое (1966). Шөгер р-нында — Микоян исем. с-зда (1932–37), битум з-дында (1946 елдан) эшли. «Үзәк» к-зы рәисе (1948 дән). 1950–74 тә «Елховнефть» НГДУда: моторист, бораулау цехы машинисты, җиһазларны ремонтлау буенча слесарь, нефть чыгару операторы (1958 дән), мастер (1967 дән). Беренчеләрдән булып бер сменада 10–12 нефть скважинасына хезмәт күрсәтүне үзләштерә. Герой исеме нефть чыгаруда җидееллык план (1959–65) йөкләмәләрен үтәгәндәге казанышлары һәм югары техник күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. Профсоюзлар һәм ВЦСПС әгъзалары съездлары делегаты (1968, 1972). Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 1нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. СССРның мактаулы нефтьчесе. Әлмәттә Геройлар аллеясында бюст, Иске Шөгер авылында барельеф куелган, Шөгернең мәктәп музеенда Геройга багышланган экспозиция оештырылган.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

*М.Җ.Гаитов.*



Ш.К. Шәрифуллин.



З.Н. Шәрифуллина.

**ШӘРИФУ́ЛЛИН** Лев Равил улы (2.2.1930, Бөгелмә кантоны Мөслим а. — 14.12.1988, Казан), галим агроном, а.х. фән. д-ры (1983), проф. (1987). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Бөгелмә р-нының Сокольский МТСнда баш агроном, «Сокольский» с-зы директоры (1957 дән). 1960 елдан Балык Бистәсе район башкарма ком-ты рәисе. 1962–65 тә Арча терр. җитештерү колхоз-совхоз идарәсе башлыгы. 1965–68 дә КПССның Әлки район ком-ты 1 нче секретаре. 1968–85 тә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында. 1985–88 дә Мари ун-тының үсемлекчелек каф. мөдире һәм проректор. Хезмәтләре агротехника, а.х. культуралары уңышын программалаштыру, сугарулы игенчелек өлкәсе мәсьәләләренә карый. 1963–67 дә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Факторы запрограммированных урожаев. К., 1974 (автордаш); Сила орошаемого поля. К., 1977; Озимая рожь. М., 1981 (автордаш); Интенсивная технология возделывания озимой ржи. К., 1989 (автордаш).

*И.Н.Афанасьев.*

**ШӘРИФУ́ЛЛИН** Фәрит Әхмәтнур улы (19.5.1939, Саба р-ны Олы Шыңар а. — 8.4.2011, Казан), журналист, тәрҗемәче, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1963), *«Мәгариф»* ж-лында: әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркәтип, баш мөхәррир урынбасары, баш мөхәррир (1989 елдан). 2003 тән ТР ФА Татар энциклопедиясе ин-тының энциклопедия басмаларын татар теленд ә әзерләү бүлегенең әдәби мөхәррирләр төркеме җитәкчесе. Мәкаләләре пед., Татарстан укытучыларының тәҗрибәләре турында. Урта мәктәп укучылары өчен химия һәм ботаника дәреслекләрен, балалар һәм яшьләр өчен әдәби әсәрләрне татар теленә тәрҗемә итә. ТРның Журналистлар берлеге бүләге лауреаты (1990). Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ф ә й з у л л и н Р. Мәгърифәт хадиме // Мәгариф. 2004. № 5.

**ШӘРИФУ́ЛЛИН** Шамил Камил улы (13.9.1949, Төрекмәнстан ССР, Чарджоу өлкәсенең Фараб пос. — 25.12.2007, Казан), композитор, педагог, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). 1973 елда Казан консерваториясен (А.Лупповта композиция классы) тәмамлый. 1972–82 елларда Идел буе халыклары музыкасы кабинеты мөдире, 1982–2001 дә Казан консерваториясендә укыта. Ш. иҗатында ислам муз.-поэтик культурасы һәм этник төркемнәрнең муз. иҗаты (татар-мишәрләр, керәшен татарлар) б-н бәйле татар фольклоры үзенчәлекле чагылыш таба, ш.у. европалы булмаган халыкларның муз. традицияләре дә (Америка индеецлары текстларына язылган «Чәчәк турында җыр» («Песнь о цветке») оратория-балеты) кулланыла. Ш. татар хор музыкасы: «Мөнәҗәтләр» (1975) һәм «Авыл көйләре» (1977) хор концертлары, «Татар туй җырлары» (1993) кантатасы һ.б. үсешенә зур өлеш кертә. Аның иҗатында милли мотивларның хәзерге Көнбатыш композиторлары музыкасы б-н үрелеп баруы күзәтелгән симф. һәм камера-инструменталь әсәрләр мөһим урын алып тора. Ш.ның «Өлкәара диалоглар» (1980) симфониясендә, симф. оркестр өчен «Җыен» (1981) концертында, «Татар биюләре» (2006) һәм «Татар буколикалары» (2006) симф. циклларында, татар музыкасында беренче фортепиано триосында; скрипка, виолончель һәм фортепиано өчен борынгы татар көйләре темасына «Борынгы болгар моңнары» (1987) дип аталган пьесалар циклында иҗади индивидуальлеге чагылыш таба. Татар халык көйләрен җыю һәм аларны бастыру Ш.га татар халкының традицион муз. культурасының зурлыгын һәм әһәмиятен күзаллау киңлеге бирә. Аның балалар һәм яшүсмерләр өчен иҗат иткән вокаль һәм инструменталь әсәрләре уку-укыту һәм концерт репертуарын баета: «Туган якта» хор кантатасы, фортепиано концерты һ.б. Шәкертләре арасында И.Байтирәк, Р.Гатауллин, Р.Абязов һ.б. бар. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2005).

Төп әсәрләре: «Йосыф һәм Зөләйха» балеты (үз либреттосына, 2005, куелмаган); Беренче симфония (1973); «Дала» симф. поэмасы (И.Байтирәк б-н автордашлыкта, 2004); Скрипка һәм фортепиано өчен соната (1970); Фортепиано өчен соната (1972), Кыллы квартет (1972), Скрипка, виолончель һәм фортепиано өчен трио (1982); Фортепиано өчен ун пьесадан торган «Борынгы халык моңнары» циклы (1988); орган өчен «Мөнәҗәтләр темасына вариацияләр» (1974) һәм «Сәйдәш елгасы» (2000) әсәрләре; җырлар (50 дән артык), татар халык җырларының хор өчен эшкәртмәләре (15 тән артык), спектакльләргә һәм телефильмнарга музыка (10 нан артык) һ.б.

*Әд.:* Ф а й з у л а е в а М.П. Древние мотивы на новый лад // Советская музыка. 1979. № 12; Ш а м с у т д и н о в а Ф.Я. Шарифуллин Шамиль // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; М а к л ы г и н А.Л. «Я словно жемчуга ловец...» // Музыкальная академия. 1992. № 2; Композиторы Татарстана. М., 2009.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ШӘРИФУ́ЛЛИНА** Зөһрә Нигъмәтулла кызы (20.12.1956, Сарман р-ны Сарман а.), эстрада җырчысы, ТРның халык артисты (1997). Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тын тәмамлый (2000). 1979 елдан ТАССРның Җыр һәм бию ансамбле солист-вокалисты, 1980 нән Татар филармониясендә И.Шакировның концерт төркемендә эшли, 1986 да үз концерт коллективын оештыра. Еш кына Россия төбәкләренә һәм БДБ илләренә концертлар б-н чыга; Мәскәү, Казакъстан, Үзбәкстан, Төркиядә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадаларында һәм көннәрендә катнаша. Ш. репертуарын шактый гына татар һәм башкорт халык җырлары, татар композиторларының вокаль әсәрләре («Сарман», «Су буенда учак яна», «Яшьлегем чишмәләре» һ.б.) тәшкил итә. 1 нче Халыкара татар җыры конкурсы лауреаты (Казан, 1988).

*Ф.Ш.Салитова.*

**ШӘРИФУ́ЛЛИНА** Эльмира Мөхәммәт кызы (4.6.1947, Мөслим р-ны Симәк а.), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1966 елдан Мамадыш шәһәрендә Пионерлар йорты директоры булып эшли. 1970 тән Казанда: ТАССР МСның Телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында мөхәррир, 1974 тән «Ялкын» ж-лында бүлек мөдире, «Яшь ленинчы» (1983–87) һәм «Мәгариф» (1993–97) г-таларында әдәби хезмәткәр. 1997–2004 тә Казан пед. көллиятендә укытучы. Ш. иҗатының төп юнәлешләре — лирика һәм балалар өчен шигырьләр. «Яңгыр җиле» (1984), «Зәңгәр эңгер» (1991), «Таң чыгы» (1998), «Уйлы еллар» (2003), «Тамды яшем» (2012) шигырь җыентыклары, «Мәхәббәтнең җиде төсе» хикәяләр һәм повестьлар җыентыгы (2007); балалар өчен «Безнең зоопарк» (1976, 4 нче басма, 1999), «Җитәкләшеп җил белән» (1990), «Ничек, нинди, ни төсле?» (2000) шигырь җыентыклары, «Иң матур әни» (1999), «Алтын балык» (2000), «Баллы балачак» (2009) әкиятләре авторы. «Мизгел» мемуарлар повесте (1986) һәлак булган ире Ф.Шәфигуллинга, «Асрамага бала бирәм» (1994), «Казаныңа ни салсаң...» (2005) очерклар җыентыклары мәгариф, пед. тарихына, халык мәгарифенең танылган эшлеклеләренә багышлана. Ш. шигырьләренә композиторлар Ә.Бакиров, Р.Яхин, Н.Җиһанов, Р.Гатауллин, И.Закиров популяр җырлар иҗат итәләр.

Ә с ә р.: Сөюемнән мин бер чибәр идем. К., 2005.

*Әд.:* Ф ә т т а х Н. Шигърият күгенә // Казан утлары. 1984. № 10.

**ШӘРКЫЯ́ТЬ ГЫЙЛЕМЕ́**, ориенталистика, Шәрекъ илләренең тарихын, икътисадын, телләрен, әдәбият, сәнгать, дин, фәлсәфә тармакларын өйрәнә торган фәннәр җыелмасы. Европада һәм Россиядә аның гамәли, акад. (классик) һәм университет юнәлешләре формалаша һәм үсеш кичерә. 19 йөздә — 20 йөз башында Шәрекъ телләре, халыкларының әдәбияты һәм тарихи истәлекләре, борынгы һәм урта гасырлар тарихы, мәдәнияте б-н бәйле классик Ш.г. интенсив рәвештә үсә. Россиядә Ш.г. фән буларак 19 йөз башында формалаша. Аның үсешенә Шәрекъ илләре б-н төрле тышкы сәяси, сәүдә-икътисади һәм фәнни багланышлар булышлык итә. Бу чорда Шәрекъкә нисбәтле күпсанлы җыелмалар һәм коллекцияләр (кульязмалар, китаплар, акчалар, сәяхәтчеләр һәм дипломатларның язмалары, фольклор, лексика үрнәкләре һ.б.) туплана, грамматикалар, хрестоматияләр, сүзлекләр, Шәрекъ халыклары тарихы һәм мәдәнияте буенча тәрҗемә һәм оригиналь әсәрләр нәшер ителә; гомуми белем бирүче дөньяви һәм дини мәктәпләрдә (ш.и.

Казандагы беренче ир балалар гимназиясендә, 1769–70), университетларда (Казан ун-тында, 1807 дән) Шәрекъ телләрен укыту кертелә. Петербург ФА Ш.г.нең бер үзәгенә әверелә (1818 елда Азия музее ачыла). Илдә Кытайны өйрәнү үсешендә Пекиндагы Россия рухани миссиясе зур роль уйный (1715 тә нигезләнә). 19 йөздә Россия Ш.г.нең төп Петербург, Мәскәү һәм Казан үзәкләре формалаша. 19 йөзнең 1 нче яртысында Казан ун-ты Россиядә Ш.г. үзәкләренең берсенә әверелә. Казан ун-ты шәркыятьче галимнәре Х.Д.Френ, Ф.И.Эрдман, А.К.Казимбәк, И.Н.Березин, И.Хәлфин, В.П.Васильев, О.М.Ключевский, П.Я.Петров, И.Ф.Готвальд, О.П.Войцеховский һ.б. Шәрекъ илләре тарихын һәм мәдәниятен, Шәрекъ телләрен һ.б.ны өйрәнүгә зур өлеш кертәләр (к. *Шәрекъ бүлеге*). 1830–40 елларда Казан ун-ты мөселман илләренә, Кытайга һәм Монголиягә фәнни экспедицияләр оештыра, филол., тарих һәм чыганакларны өйрәнү өлкәләрендә зур тикшеренүләр уздырыла. Монгол телләре каф. профессорлары О.М.Ковалевский һәм А.В.Попов Казанда һәм Россиядә университет Ш.г.нә нигез салучылардан булалар.

Шәрекъ бүлеге Казаннан Петербург ун-тына күчерелгәннән соң (1855), Казан Ш.г.нең кысалары тарая, башлыча элеккечә тюркология, ислам мәсьәләләре өйрәнелә (Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.С.Саблуков, И.Ф.Готвальд, Н.И.Ильминский, Н.Ф.Катанов, Н.И.Ашмарин, В.В.Радлов, И.А.Бодуэн де Куртенэ, М.Бигиев, П.Жузе һ.б.).

1917–20 елларда яңа акад. фәнни учреждениеләр һәм югары уку йортлары формалаша, Шәрекънең ул замандагы хәлен өйрәнүгә кызыксыну тәгаенләнә, Европа ориенталистикасы һәм Шәрекътәге чит илләр б-н фәнни элемтәләр йомшара, Ташкентта, Бакуда, Киевта, Иркутскида һ.б.да Ш.г.нең яңа үзәкләре барлыкка килә. Совет чорында Казанда Ш.г. тарихи, археол., филол., сәнгати һ.б. гуманитар тикшеренүләр б-н тыгыз бәйле була (к. *Татар мәдәнияте йорты*). 1920–40 елларда Казан Ш.г. традицияләрен Г.Ибраһимов, Г.Гобәйдуллин, Һ.Атласи һ.б. дәвам итерәләр. Татар тел белеме үсеше Җ.Вәлиди, Г.Алпаров, В.А.Богородицкий, Г.Рәхим, М.Корбангалиев, Р.Газизов, Г.Шәрәф һ.б.ның фәнни эшчәнлеге б-н тыгыз бәйле. 1939 да Казанда Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү ин-ты, 1944 тә Казан ун-тында татар филологиясе бүлеге ачыла, алар Казан Ш.г.нең төп үзәкләренә әвереләләр. 1960 еллардан аның үсешендә төп этап башлана, татар халкы тарихы, археологиясе, теле, әдәбияты, фольклоры, иҗтимагый-фәлсәфи фикере һәм этнографиясе, Идел буе һәм Урал алды халыкларының үзара багланышлары һәм йогынтысы мәсьәләләре буенча тикшеренүләр дәвам итә (М.Г.Госманов, Р.М.Вәлиев, Н.Г.Мәҗитова, С.М.Михайлова, Х.Й.Миңнегулов, М.З.Зәкиев, Ф.С.Фәсиев, Ә.Г.Кәримуллин, Я.Г.Абдуллин һ.б.). Археол., археографик һәм фольклор экспедицияләре оештырыла. Әлеге тикшеренүләр халык авыз иҗаты әсәрләрен, иске татар, гарәп, фарсы, төрек һ.б. шәркый телләрдәге борынгы кульязмаларны һәм китапларны җыюдан гыйбарәт була (к. *Археографик экспедицияләр*). Башлыча Казан ун-ты китапханәсендә, Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты мирасханәсендә тупланган әлеге кульязмалар һәм китаплар шәркыятьче галимнәрдә зур фәнни кызыксыну уята. Атаклы татар галимнәре, әдипләре, илаһият галимнәре, шагыйрьләре һәм сәясәт эшлеклеләре Кол Гали, Котб, Мөхәммәдъяр, Кол Шәриф, Г.Курсави, Г.Утыз Имәни, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Х.Фәезханов, Б.Вәисов, Г.Баруди, Г.Гомәри, З.Камали, М.Бигиев, Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими, Г.Исхакый Ф.Туктаров, М.Солтангалиев һ.б. мирасын өйрәнү дәвам итә. Респ-ка галимнәре тарафыннан Казан Ш.г. тарихы, Азия һәм Африка илләренең хәзерге үсеше һәм исламны өйрәнү, Шәрекътәге эллинизм дәвере дәүләтләренең халыкара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре, төрки телле язма чыганакларны өйрәнү, татар тел белеме һ.б. буенча күпсанлы хезмәтләр нәшер ителә. Казан Ш.г. хәзерге этапта уку йортларында Шәрекъ телләрен укытуның яңарышы, Казан ун-тының Ш.г. ин-ты ачылу (2000), респ-када традицион мөселман югары уку йортлары эшчәнлеге башлану, Шәрекътәге чит илләр б-н фәнни һәм мәдәни багланышлар киңәю, Ш.г. буенча яшь белгечләр әзерләүнең тирәнәюе һәм, гомумән, илдәге классик Ш.г. традицияләренең баетылуы б-н сыйфатлана. Ш.у.к. *Татар халкын өйрәнү гыйлеме, Тюркология*.

*Әд.:* К р а ч к о в с к и й И.Ю. Очерки по истории русской арабистики // Избр. соч. М.–Л., 1958. Т. 5; Проблемы тюркологии и востоковедения. К., 1964; Развитие филологических и исторических наук. К., 1969; З а к и е в М.З. Успехи татарского языкознания за 50 лет // Вопросы тюркологии. К., 1970; К у з н е ц о в а Н.А., К у л а г и н а Л.М. Из истории советского востоковедения. 1917–1967. М., 1970; М а з и т о в а Н.А. Изучение Ближнего и Среднего Востока в Казанском университете (первая половина XIX в.). К., 1972; Д а н ц и т Б.М. Ближний Восток в русской науке и литературе. М., 1973; Б а р т о л ь д В.В. Работы по истории востоковедения // Соч. М., 1977. Т. 9; Л у н и н Б.В. Средняя Азия в научном наследии отечественного востоковедения: Историогр. очерк. Таш., 1979; М а х м у т о в а Л.Т. Татарское языкознание. Итоги и проблемы // Проблемы современной тюркологии. А.-А., 1980; Ш а м о в Г.Ф. Профессор О.М.Ковалевский: Очерк жизни и научной деятельности. К., 1980; К о н о н о в А.Н. История изучения тюркских языков в России: Дооктябрьский период. Л., 1982; К у л и к о в а А.М. Становление университетского востоковедения в Петербурге. Л.. 1982; А б д у л л и н Я.Г., Ш а й д у л л и н а Л.И. Востоковедение в Казани // Народы Азии и Африки. М., 1985; История отечественного востоковедения до середины XIX в. М., 1990; В а л е е в Р.М. Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX в. — 20-е гг. XX в.). К., 1998.

*Р.М.Вәлиев.*

**ШӘРЛӘРӘМӘ́** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 301 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шарлы (1751), Шарлы Әрем (1816) исемнәре б-н билгеле. 18 — 19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 ашлык саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2908,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда, 1920 дән ТАССР-ның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1795 тә — 36, 1816 да — 162 ир-ат; 1834 тә — 437, 1870 тә — 976, 1897 дә — 739, 1906 да — 668, 1920 дә — 898, 1926 да — 712, 1938 дә — 728, 1949 да — 541, 1958 дә — 506, 1970 тә — 598, 1979 да — 461, 1989 да — 309, 2002 дә — 306 кеше.

**«ШӘРУ́К БЕ́ГЛЫЙ»**, «качкыннар циклы»ннан татар *тарихи җыры*. Герое — Самара губернасының Самат (Аламат, Оламат) авылы кешесе, чын прототибы бар дип фараз ителә. Ярлы крәстиян гаиләсендә туа, батыр, кыю егет буларак танылa. Тотыла һәм Себергә җибәрелә, кача. Урманнарда каңгырып йөри, «гадел юлбасар» тормышы алып бара: байларга һөҗүм итә, алардан тартып алганны ярлыларга өләшә. Җырда солдатларның армиядәге, мәхбүсләрнең төрмәдәге һәм сөргендәгеләрнең авыр хәле тасвирлана. Строфаларына рефрен хас: «Самат урманнары бигрәк зур, / Качкыннарга михнәт бигрәк зур». «Ш.б.»дагы вакыйгаларның сәнгать фоны булып Самара губернасының «кара урман»нарын тасвирлау хасил итә.

Җыр 1940 елда Самара өлкәсе Барыш р-нының Калды авылында язып алына. Күпсанлы вариантлары Ульянов өлкәсенең татар авылларында теркәлә. Беренче тапкыр «Татар халык җырлары»нда басыла (1965). Кульязма вариантлары ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондында саклана.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988; У р м а н ч е Ф. Татар халык иҗаты: Дәреслек. К., 2005.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ШӘҮЛЕГӘННӘ́Р** (Oriolus), шәүләгән кошлар семьялыгыннан сайрар кошлар семьялыгы. Евразия һәм Төньяк-Көнбатыш Африкада таралганнар. РФдә көнбатыш чиктән Енисейга кадәр булган катнаш һәм яфраклы урманнарда яшиләр. ТРда бер төре — гади шәүлегән (O. oriolus) бар. Гәүдәсенең озынлыгы якынча 25 *см*. ТР фаунасында иң ачык төстәге кошларның берсе. Ата кошларның каурый капламы алтынсу-сары, канатлары, койрыгы һәм томшыгыннан күзенә таба үтүче буй кара төстә. Ана һәм яшь кошлар саргылт-яшел, түшләрендә ак бөрчекләр бар. Күчмә кош. ТР терр-ясендә, гадәттә, май уртасында күренә башлыйлар. Оясын кәрзин рәвешендә кыяклыларның сабы һәм яфракларыннан, юкә кайрысыннан, киндер сүсеннән, туз һәм йоннан зур агачларның (имән, каен, нарат) ян ботаклары үсеп чыккан урыннарда, 2 дән 20 *м* га кадәрге биеклектә кора. 3–6 йомырка сала; ана кош утыра. Оялау чоры дәвамында ата кошлар туктаусыз сайрыйлар. Сайраулары әкрен генә чәрелдәгән авазларга флейта тавышы килеп кушылуны хә-

терләтә. Оядан чыккан кош балалары олылары б-н августка кадәр бергә булалар. Кышлау өчен сентябрьдә Африкага очып китәләр. Корткычларны — май һәм июнь коңгызларын, бронзаклар, яфрактөргечләр, яфрагашарлар, филчекләр, төрле гусеницаларны юк итеп урманнарга зур файда китерәләр. Җиләк һәм җимешләре б-н тукланып, урман агач һәм куакларының таралуына булышлык итә.

**ШӘФӘ́КЪ ЧЫПЧЫГЫ́** (Erithacus rubecula), миләш чыпчыгысыманнар семьялыгыннан сайрар кош. Европа, Азия һәм Төньяк Африкада таралган. ТР терр-ясенең барлык районнарында очрый. Куаклы һәм чыбык-чабыклы төрле типтагы урманнарда яши, парк, бакча, урман полосаларында оялый. Гәүдәсенең озынлыгы якынча 15 *см*, авырлыгы 15–20 *г*. Аркасы, канатлары һәм койрыгы кара тимгелле коңгырт төстә, муены һәм күкрәге кызгылт сары-җирән, бүксәсе ак. Аяклары чагыштырмача биек. Җирдә сикереп хәрәкәтләнә. Күчмә кош. Апрельдә беренче булып ата кошлар очып килә; кояш чыкканнан соң һәм шәфәкъ вакытында (исеме шуннан) озак кына сайрыйлар. Ояларын җирдә яки түмгәктә, агач кәүсәләре ярыкларында, чыбык-чабык өемнәрендә коралар. Көрән вак тимгелле 5–7 саргылт-ак яки аксыл сары-алсу йомырка салалар. Үрмәкүч, суалчан, вак лайлачлар, ш.у. бөҗәкләр, көзен җиләк һәм орлыклар б-н тукланалар.

**ШӘФИГУ́ЛЛИН** Айрат Радин улы (15.9.1965, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. канд. (2003), ТРның атказ. икътисадчысы (2007). Казан финанс-икътисад ин-тын (1990), Россия икътисад академиясен (Мәскәү, 2003), РФ Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясен (2011) тәмамлый. 1990–91 елларда халык депутатларының Совет район советы башкарма ком-тында бүлек мөдире. 1992–95 тә Казанның Совет районы хакимиятендә бюро мөдире, 1995–97 дә хакимият башлыгының беренче урынбасары, 1997–98 дә Казан хакимиятенең финанс идарәсе башлыгы, 1998–2007 дә РФнең ТР буенча Пенсия фонды бүлеге идарәчесе. 2007–2014 тә ТРның Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министры. 2014 тән ТР Куркынычсызлык Советы секретаре. Хезмәтләре халыкны социаль яклау, РФнең пенсия системасы үсеше мәсьәләләренә карый. Почёт ордены (2011), медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘФИГУ́ЛЛИН** Александр Гаврилович (23.4.1905, Казан губ., Чистай өязе Туймәт а. — 1971, Мәскәү), физик, физика-матем. фән. д-ры (1949), проф. (1949), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1954). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1936), Мәскәү оешмаларында эшли. 1942–44 елларда Монгол ун-тының (Улан-Батор) физика каф. мөдире. 1948–49 да СССР Югары белем бирү министрлыгының ун-тлар буенча Баш идарәсе башлыгы урынбасары. 1949–55 тә Казан ун-тының проректоры һәм, бер үк вакытта, молекуляр физика каф. мөдире. 1955 тән Мәскәүдә. Хезмәтләре җылылык һәм молекуляр күренешләр физикасына карый.

Х е з м.: Исследование физическими методами некоторых цепных реакций в жидкой фазе. К., 1952; Применение физических методов в химической кинетике. К., 1955.

*Р.Г.Усманов.*

**ШӘФИГУ́ЛЛИН** Вәли Сәлимулла улы (4.8.1894, Казан губ., Тәтеш өязе Борнаш а. — 9.10.1939, Норильск ш.), сәясәт эшлеклесе, журналист. 1913 — 14 елларда Ташкент басмаханәләрендә һәм газеталары редакцияләрендә эшли. 1915 тә Казаннан хәрби хезмәткә чакырыла, Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. РСДРП(б) әгъзасы (1917 нең апрелennән). Мөселман социалистлар ком-тын оештыручыларның берсе һәм аның секретаре (1917); аның басма органы «Кызыл байрак» г-тасы редколлегиясе әгъзасы («М.Вәли», «В.Сәлим» тәхәллүсләре б-н революцион эчтәлекле мәкаләләр бастыра). Казандагы 1917 елгы Окт. кораллы күтәрелеше чорында Хәрби-революцион ком-т составына сайлана. 1918 нең башында 2 нче Бөтенроссия мөселман гаскәриләре корылтаен әзерләүдә катнаша. Казан Чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык армиясе частьларыннан азат ителгәннән соң (1918 нең сентябре), «Эш» г-тасының баш мөхәррире. 1919 ның апрелендә РКП(б)ның Казан губкомы каршындагы нәшрият коллегиясе әгъзасы итеп билгеләнә. Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының 2 нче Бөтенсоюз съездында катнаша (1919, Мәскәү), РКП(б) ҮК каршындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмалары Үзәк бюросына һәм бюро басмаларының — «Эшче» г-тасының һәм «Кызыл Шәрекъ» ж-лының баш мөхәррире булып сайлана. 1920 нең җәендә, ТАССР оештырылганнан соң, респ-каның татар телендәге беренче газетасы «Татарстан хәбәрләре»нең баш мөхәррире итеп билгеләнә. Язмалары Татарстандагы революцион хәрәкәткә һәм соц. төзелешнең беренче елларына багышлана. 1921 елгы корылык чорында Ш. ТАССР Игенчелек халык комис-ты хезмәткәре итеп билгеләнә. 1922 дән «Җир һәм урман» оешмасы хезмәткәрләре профсоюзларының өлкә бүлеге рәисе. 1925–29 да Татиздат директоры. ВКП(б) ҮК каршындагы марксизм-ленинизм курсларын тәмамлаганнан соң (Мәскәү, 1931), ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты матбугат бүлеге мөдире булып эшли; Татгосиздатның баш мөхәррире, соңрак сәнгать секторы мөдире. 1933 тә Балык Бистәсе МТСының сәяси бүлеге башлыгы итеп билгеләнә. 1930 еллар уртасында Россия телеграф агентлыгынын Татарстан бүлеге мөдире. Репрессияләнә (к. «*Троцкийчыларның контрреволюцион-террорчылык оешмасы» эше*); үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Н а с ы р о в Т.М. Шафигуллин Вали Салимуллович // Борцы за счастье народное . К., 1967.

**ШӘФИГУ́ЛЛИН** Зәйдулла Абдулла улы (25.4.1932, Чистай р-ны Мөслим а. — 23.12.2002, Казан), журналист, РСФСРның, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1978, 1993). Казан ун-тын (1961) тәмамлый. 1956 елдан «Татарстан яшьләре» г-тасында әдәби хезмәткәр, 1957–61 дә «Совет Татарстаны» г-тасының үз хәбәрчесе. 1963–93 тә «Социалистик Татарстан» (1992 дән «Ватаным Татарстан») г-тасы үз хәбәрчесе, бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип. 1993–96 да ТР Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы каршындагы Матбугат ирекен яклау буенча дәүләт инспекциясе башлыгы. 1996–2002 дә «Мәдәни җомга» г-тасының хәбәрче-тәрҗемәчесе, мәгълүмат бүлеге мөдире, аннан соң публицистика бүлегендә. Иҗтимагый-сәяси темага караган, татар милләте үсеше, аның мәдәниятен һәм динне торгызу мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләр авторы. «Ислам: Белешмә-сүзлек»не (1993) төзүче. ТАССР Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. бүләге лауреаты.

Ә с ә р.: Авыл киләчәккә карый: Ерактагы яктышыма хатлар. К., 1973; Җырлар туган җирдә. К., 1981 (автордаш); Кавышулар бик күңелле... К., 1986.

**ШӘФИГУ́ЛЛИН** Лотфулла Нурислам улы (1.5.1955, Арча р-ны Симетбаш а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, химаяче, РФнең атказ. элемтә хезмәткәре (2014), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2018). Камышин югары хәрби командирлар-төзелеш ун-тын (1975), Халыкара менеджмент академиясен (1992), Чиләбе ун-тын (1999) тәмамлый. 1975–91 елларда СССР Хәрби Көчләрендә. 1991 дән «Татмясопром» ҖБдә («Татарстан ит сәнәгате» холдинг компаниясе): 1993 тән ген. директор урынбасары, вице-президент. 1998 дән ТР Дәүләт милке б-н идарә итү дәүләт ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары, 2001 дән ТР җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрының 1 нче урынбасары. 2006 дан «Таттелеком» АҖ ген. директоры. ТР Дәүләт Советы депутаты (2009 дан). Дәүләт бүләге мәдәният өлкәсендә мөһим проектларны тормышка ашыруга һәм рухи кыйммәтләрне торгызуга, Татарстан халыкларының милли кыйммәтләрен һәм тарихи мирасын саклауга керткән өлеше өчен бирелә. Медальләр һәм ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ШӘФИГУ́ЛЛИН** Равил Хасият улы (1.12.1941, Куйбышев (хәзер Ульянов) өлкәсе Мәләкәс (хәзер Димитровград) р-ны Парау а.), язучы, җәмәгать эшлеклесе. Ульянов өлкәсе татар язучылары берләшмәсе рәисе. Мәләкәс а.-х. техникумын тәмамлый (1963). 1972-94 елларда Сахалинда яши: «Роснефть» корпорациясенең «Сахалинморнефтегаз» җитештерү берләшмәсендә кадрлар бүлеге башлыгы вазифаларын башкара. 1994 тә Димитровград шәһәренә күченеп кайта. Әсәрләре ТР газета-журналларында, «Өмет» (Ульянов ш.) г-тасында басылып килә. Туган җиргә, туган телгә мәхәббәт, яшәү мәгънәсе, тормыш гаме турындагы фәлсәфи уйланулар тулы шигырьләре һәм хикәяләре тупланган «Күңел дәрьялары» (2007), «Серле Парау» (2008), «Теге ярда» (2012), «Үреләм йолдызларга» (2016) исемле җыентыклар авторы. «Габдельджаббар Кандалый. Через призму современности» (2015) һәм «Гакиль Сагиров. О себе и все о нем ...» (Самара, 2015) китапларының автордашы.

**ШӘФИГУ́ЛЛИН** Фаил Хафиз улы (18.5.1939, Яшел Үзән р-ны Карашәм а. — 7.10.1982), язучы. Казан ун-тын тәмамлый

(1973). Хезмәт юлын 1953 елда эшче буларак башлый. 1973–82 дә «Казан утлары», «Чаян» ж-ллары редакцияләре хезмәткәре. Ш.ның беренче шигырьләре вакытлы матбугатта 1958 дә күренә башлый. Әсәрләренең лирик герое үзендә милли характерның туган җиргә мәхәббәт, хезмәт сөючәнлек, шәфкатьлелек кебек иң яхшы сыйфатларын берләштерә. Ш.ның поэтик стиленә татар теленең нечкәлекләрен тою, читләтеп әйтү манерасы хас («Яңа ел бусагасында», 1967; «Гашыйк», 1969; «Дулкынга дулкын», 1977). Авторга балалар һәм яшүсмерләр өчен «Өй салуның ние бар...» (1991), «Ак яллы аргамаклар» (1980), «Бәхет йолдызы астында» (1982), «Ак маңгайлы бүреләр» (1985) повестьлары, «Авылым сандугачы» (1968), «Каен яктысы» (1972), «Тау битендә күләгә» (2001) хикәяләр җыентыклары, ш.у. «Күзгә карап» (1979), «Көтелмәгән хәлләр» (русчага тәрҗемәдә «Снег на голову», 1983), «Бер атуда — ике куян» (1999) юмор һәм сатира җыентыклары танылу китерәләр. Алар 1970–80 еллар татар прозасының аерым бер юнәлешен тәшкил итәләр. Ш. заманның тирән яра калдырган сугыш нәтиҗәләре, авылдашларның яхшы тормыш эзләп китеп туган җирләреннән аерылулары һәм, нәтиҗә буларак, буыннар арасындагы рухи элементның өзелүе, әхлак нигезләренең какшавы кебек авыр якларын төгәл билгели. Ш.ның күп кенә әсәрләре автобиографик характерда. Үзенең тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләрендә («Кешелек тавы» җыентыгы, 1988) ул балалар әдәбияты мәсьәләләрен яктырта, яшь буынга багышланган әсәрләрдә рухи башлангычның әһәмиятен ассызыклый. Ш. әсәрләре рус теленә тәрҗемә ителә. ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы, медальләр б-н бүләкләнә. 1995 тә Яшел Үзән шәһәренең милли төбәкне өйрәнү китапханәсенә язучының исеме бирелә, ә 1999 да шунда аның музей бүлмәсе ачыла.

*Әд.:* М о с т а ф и н К. Сандугач җыры дәвамлы булсын // Казан утлары. 1969. № 3; К у к у ш к и н Р. Диңгезче егет моңы // Казан утлары. 1985. № 3.

*Р.Ф.Шәфигуллина.*

**ШӘФИГУ́ЛЛИННАР**, бертуган Иркутск сәүдәгәрләре, җәмәгать эшлеклеләре, иганәчеләр. Чыгышлары б-н Казан губернасы Цивильск өязеннән. 1894 елда «Бертуган Шәфигуллиннар сәүдә йорты»н нигезлиләр. Иркутск, Красноярск, Чита шәһәрләрендә затлы мех, киемнәр сату кибетләре тоталар. Казанда «Борнаев һәм Шәфигуллин» сәүдә йорты була, Идел буе төбәгендә сәүдә б-н шөгыльләнә. 1) **Заһидулла** (16.12.1840, Акъегет а. – 1919, шунда ук), 19 йөз ахырыннан җәдиди ысулда укыту тарафдары була; Казан губернасы Зөя, Тәтеш, Цивильск өязләрендә мәчет, мәдрәсә, мәктәпләр салдыра, ш.и. аның акчасына Акъегет авылында 1890 да — мәдрәсәле икенче, 1899–1900 дә өченче мәчетләр, 1898 дә Казан губ. Цивильск өязендәге бердәнбер җәдиди ир балалар мәктәбе (интернат тибында була, анда Буа, Тәтеш, Зөя өязләреннән дә килеп укыйлар), 1906 да соңрак рус-татар мәктәбе итеп үзгәртелгән кыз балалар мәдрәсәсе төзелә. 1910 елларда әлеге уку йортлары шәкертләренең саны 442 кешегә җитә. 20 йөз башында татар җәмәгать оешмалары эшендә актив катнаша, Бөтенроссия мөселманнары корылтайларына вәкил итеп сайлана. 2) **Шәйхулла** (1853, Казан губ. Цивильск өязе, хәзер Яшел Үзән р-ны Акъегет а. – ?), 2 мәртәбә Иркутск шәһәр Думасы гласныйлыгына, Биржа ком-тына сайлана. 1877–78 еллардагы рус-төрек сугышында катнаша, медальләр б-н бүләкләнә; Ш. 1887 дә Иркутскида мөселманнар өчен гыйбадәтханә ачалар, 1902 дә үз акчаларына таш мәчет салдыралар, аның каршында мәдрәсә һәм кыз балалар өчен җәдиди ысуллы мәктәп эшли. Акъегет авылында Заһидулла Ш. йорты — 19 йөз ахыры архит-ра истәлеге саклана (мәчет буларак файдаланыла).

*Әд.:* И б р а һ и м о в Г. Әсәрләр: 8 томда. VII т. К., 1987. Б. 358–359; М ө с л и м о в А. Мәгърифәтле муллалар // Ватаным Татарстан. 1991. 17 һәм 24 май; Т и м е р ш и н И.Г. Акъегет авылы тарихы сәхифәләре. К., 2001.

**ШӘФИ́ЕВ** Мөнир Шәйдулла улы (22.6.1949, Әлки р-ны Иске Алпар а. — 16.2.2007, Казан), эпидемиолог, мед. фән. д-ры (1990), проф. (2000), ТРның атказ. табибе (2000). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), шунда ук эпидемиология кафедрасында эшли, 1994 елдан каф. мөдире, бер үк вакытта, 1984–86 да, ин-тның патентлар бүлеге мөдире. Ш. тышкы тирәлек факторлары тәэсирендә кешенең иммун халәте үзгәрешен өйрәнү буенча комплекслы эксперименталь-эпидемиологик тикшеренүләр үткәрә.

Х е з м.: Эпидемиология катастроф. К., 1992 (автордаш); Эпидемиология и профилактика токсоплазмоза. К., 2006 (автордаш).

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**ШӘФИ́КОВ** Динмөхәммәт Сәйфетдин улы (26.11.1941, Мамадыш р-ны Түбән Ушма а. — 30.5.2013, Лаеш р-ны Сокуры а.), галим агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1965), Арча р-ның «Северный» с-зында бөртеклеләр бүлегендә идарәче, өлкән агроном (1969 елдан), орлыкчылык с-зы идарәчесе (1976 дан), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында фәнгә хезмәт күрсәтү цехы башлыгы (1977 дән) булып эшли. Дәүләт бүләге ТРда сәламәтләндерелгән нигездә бәрәңге орлыкчылыгы системасын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ШӘФИ́КОВА** Кәүсәрия Фидаи кызы (3.1.1949, БАССРның Яңавыл р-ны Исәнбай а. — 5.5.2017, шунда ук), шагыйрә. Бала вакытыннан инвалид. 1970 елдан вакытлы матбугатта басыла. Шигырьләре коллектив «Кызлар җыры» (1977), «Бер тауда ун чишмә» (1992), «Яңавыл бизәкләре» (1994), «Сәйләннәр» (Уфа, 1998) җыентыкларына кертелгән. «Ике аккош» (Уфа, 1995; автордашы Р.Мөхәммәтдин), «Ачам күңел сандыгымны» (Уфа, 2006), «Мәхәббәт өермәсе» (Уфа, 2007; автордашы Р.Мөхәммәтдин), «Җанымда — тормыш шавы» (Уфа, 2008) җыентыклары авторы. Ш. поэзиясе сафлыгы һәм дөньяны хисләр аша кабул итүе б-н аерыла. Ул туган җир табигатен, замандашының бай эчке дөньясын мактап җырлый. Ш.ның күп кенә шигырьләренә композиторлар көйләр яза: «Берсе — кояш, берсе — ай» җыентыгы (Уфа, 2006). Шулай ук кыска хикәяләр һәм новеллалар иҗат итә: «Күз яшьләрең — көмеш тамчы» (Уфа, 2001), «Җан авазы» (Уфа, 2007), «Күңелем бизәкләре» (Уфа, 2007) җыентыклары.

*Әд.:* Ш ә ң г ә р ә е в И. Кешеләрнең елар чакта көлгәннәрен янып сөям... // Кызыл таң. 1994. 22 март.

**ШӘФЫ́ЙКОВА** Рисәлә Әхәт кызы (28.12.1940, Саба р-ны Миңгәр а. — 16.10.1997, шунда ук), вирусолог, вет. фән. д-ры (1991), проф. (1993). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук эшли, бүленеп, 1970–84, 1992–97 елларда вирусология кафедрасында. 1966–70 тә Мәскәү вирус препаратлары фәнни-тикшеренү ин-тында. 1984–92 дә Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан). Хезмәтләре сарыкларда хламидиягә бәйле абортны ачыклау өчен диагностикумнар һәм махсус профилактика препаратлары эшләүгә карый. Медаль б-н бүләкләнә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995).

Х е з м.: Получение антител для диагностики энзоотического аборта овец с помощью РСК // Ветеринария. 1975. № 6 (автордаш); Хламидио крупного рогатого скота // Ветеринария. 1990. № 2 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘЛӘ́Р** (йорт, гаилә китапханәләре), аерым бер кеше яки гаилә милкендәге китаплар җыелмасыннан гыйбарәт. Россиядә 1990 еллар башында аларның саны җәмәгать файдалануындагы китапханәләрдән 8–10 тапкыр артып китә һәм гомуми фондлары 30 млрд. тирәсе томны хасил итә. Шулай ук үз чорының китап мәдәнияте, хуҗасының шәхесе, аның ихтыяҗлары, мәнфәгатьләре даирәсе турында күзалларга ярдәм итә һәм *биографика* предметы булып исәпләнә. Казан төбәгендә төрле катлаулар (дворяннар, руханилар, сәүдәгәрләр) һәм һөнәрләр (галимнәр, укытучылар, түрәләр, сәнгать эшлеклеләре) вәкилләре милкендәге китапханәләр булуы мәгълүм. Ш.у.к. *Агафонов Н.Я. шәхси китапханәсе, Арцыбашев Н.С. шәхси китапханәсе, Әмирхан Ф. шәхси китапханәсе, Апанаевлар шәхси китапханәсе, Баруди Г. шәхси китапханәсе, Булич Н.Н. шәхси китапханәсе, Вахиди С. шәхси китапханәсе, Готвальд И.Ф. шәхси китапханәсе, Каменев Г.П. шәхси китапханәсе, Мәрҗани Ш. шәхси китапханәсе, Максуди Ә. шәхси китапханәсе, Потёмкин Г.А. шәхси китапханәсе, Полянский В.И. шәхси китапханәсе, Фукс К.Ф. шәхси китапханәсе, Шидловский И.А. шәхси китапханәсе.*

**ШӘХСИ́ ЯРДӘМЧЕ́ ХУҖАЛЫ́К**, шәхси ихтыяҗлар өчен а.х. продукциясе җитештерү һәм эшкәртүнең эшмәкәрлеккә карамаган тарихи формасы, өстәмә керем чыганагы.

СССРда шәхси хуҗалыкларның йорт яны кишәрлекләре һәм продукция өчен терлек

тоту нормалары колхозчылар өчен Колхозларның үрнәк уставында (1969) билгеләнә, эшчеләр һәм хезмәткәрләр өчен аерым норматив актлар эшләнә. Иҗтимагый җитештерү арткан саен а.х.ның тулай продуктында Ш.я.х. өлеше кими бара. Совет хакимияте чорында һәм хәзерге вакытта а.х. продукциясенең шактый өлеше Ш.я.х.ларда җитештерлә. 1940 елда тулай җитештерү күләменең — 65% ы, яшелчәнең — 48%, итнең — 72%, сөтнең — 77%, йомырканың — 94%, йонның — 39% ы алар өлешенә туры килә. 1972 дә тиңдәшле рәвештә бәрәңгенең 62%, яшелчәләрнең 36%, ит һәм сөтнең 34%, йомырканың 47%, йонның 20% ы Ш.я.х.ларда җитештерелә. 1990 елларда яшелчә һәм терлек продукциясенең аерым төрләрен җитештерүдә Ш.я.х.лар сизелерлек роль уйныйлар. Продукциянең күп өлешен җитештерүчеләр үзләре кулланалар, бер өлеше колхоз базарларында, дәүләткә, кулланучылар кооперациясенә, кооперативларга, эре күмәк хуҗалыкларга һ.б.га сатыла. Соңгылары Ш.я.х.ларга продукция җитештерүдә, ш.и. йорт яны кишәрлекләрен эшкәртүдә үз техникалары б-н ярдәм итәләр. Ш.я.х.лардагы терлекләр, башлыча, җәмәгать карамагындагы а.х. җирләрендә әзерләнгән терлек азыгы б-н тәэмин ителә.

2004 тә ТРда җитештерелгән а.х. продукциясенең гомуми күләме структурасында Ш.я.х.лар өлеше 45% тәшкил итә; 25,8 млрд. сумлык продукция җитештерелә, шул исәптән үсемлекчелектә — 14,5 млрд. сумлык, терлекчелектә 11,2 млрд. сумлык.

ТРда Ш.я.х.ларда 102805 *га* чәчүлек җирләре, ш.и. 89,8 мең *га* бәрәңге, башка төр яшелчә — 10,4 мең *га*, терлек азыгы җирләре — 2,6 мең *га*. 2004 тә респ-каның Ш.я.х.ларында 1355,3 мең *т* бәрәңге, ачык грунтта 233,6 мең *т* яшелчә җитештерлә.

Респ-каның шәхси хуҗалыкларында 2004 елда 84,8 мең *т* ит (тере авырлыкта), 570,8 мең *т* сөт, 276,4 меңданә йомырка җитештерелә.

Хәзерге этапта Ш.я.х.лар гамәлгә кертелү б-н бәйле рәвештә туган мөнәсәбәтләр хокукый яссылыкта РФнең «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 ел 7 июль Федераль законы нигезендә көйләнә.

*Әд.:* Зиятдинов Ф.С. Ресурсный потенциал АПК: анализ, оценка и эффективность использования. К., 2001; Шайдуллин Р.В. Крестьянство Татарстана: экономический и общественно-политический аспект (1920–1929 гг.). К., 2004.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ШӘҺӘ́Р АГЛОМЕРА́ЦИЯСЕ** (лат. agglomero — кушам, туплыйм, тутырам), торак пунктлар урнашуның компактлы терр. берлеге, күптөрле интенсив бәйләнешләр (производство, хезмәт, мәдәни-көнкүреш, рекрацион) б-н күпкомпонентлы катлаулы динамик системага берләшү нигезендә барлыкка килә. Гадәттә, бер яки берничә шәһәр җирлегендә (алар оештыручы үзәк ролен уйный) һәм алар янындагы торак пунктларда формалаша.

ТРда Казан–Яшел Үзән сәнәгать төйнәлеше җирлегендә Казан (1231878 кеше), Яшел Үзән шәһәре (99235 кеше), шәһәр тибындагы Васильево, Карамалы Тау посёлоклары һ.б. динамик үсештәге эре Казан Ш.а. барлыкка китерәләр. Агломерациянең үзәге — Казан, аның исә оештыру функцияләре сәнәгать тупланышы, инфраструктура, фән, югары һәм урта белем бирү учреждениеләре, транспорт һәм элемтә чаралары, ш.у. шәһәрнең башкала функцияләрен үтәү б-н бәйле. Казан агломерациясе чикләрендә барлык респ-ка халкының 36% ы, ш.и. барлык шәһәр халкының 43% ы яши. Ш.а. формалашу процесслары респ-каның төньяк-көнчыгышында (Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Зәй базасында) һәм көньяк-көнчыгышында (Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Азнакай, Баулы) күзәтелә.

*Әд.:* Лаппо Г.М. Города на пути в будущее. М., 1987; Маергойз И.М. Географическое учение о городах. М., 1987; Мустафин М.Р., Хузеев Р.Г. Всё о Татарстане: Экономико-геогр. справ. К., 1994; Хуснутдинов С.Р. Устойчивое развитие современных городов // Вестн. Казанского технол. ун-та. — 2010. № 2. — С. 421–429.

*О.В.Пьянова.*

**ШӘҺӘ́Р ДУ́МАСЫ**, шәһәр үзидарәсенең боеручы органы. 1785 елда «Россия империясе шәһәрләренә хокуклар һәм файдалар грамотасы» («Грамота на права и выгоды городам Российской империи») буенча Екатерина II тарафыннан оештырыла. Ш.д.на шәһәр магистратлары һәм ратушасы вазифаларының бер өлеше күчә. 6 катлау разрядларына (күчемсез милек хуҗалары; гильдия сәүдәгәрләре; цех һөнәрчеләре; чит шәһәр һәм чит ил «кунаклары»; күренекле гражданнар; посад кешеләре) бүленгән шәһәр халкы шәһәр җыелышында шәһәр башлыгы җитәкчелегендә Гомуми Ш.д.н, ш.у. магистратка бургомистрлар һәм ратманнар сайлый. Гомуми Ш.д. 3 елга бер тапкыр яки кичектергесез очракларда җыела. Гамәли мәсьәләләрне хәл итү өчен Гомуми дума Алты гласныйдан торган дума сайлый, анда һәр катлау разрядыннан бер вәкил керә. Шәһәр башлыгы рәислек итә. Барлык сайланулы вазифаларга карата катлау бүленеше гамәлдә, теге яки бу төркем өчен нинди вазифалар биләү мөмкинлеге билгеләнә. Шәһәр башлыклары башлыча 1 нче һәм 2 нче гильдия сәүдәгәрләрдән, 1836 дан мещаннардан сайлана. Шәһәр үзидарәсендәге сайланулы вазифаи затлар хезмәт хакы алмыйлар. 1854 тән, Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы бетерелгәч, Ш.д.нда татарларга да катнашырга рөхсәт ителә, ләкин анда алар тавышларның 1/3 өлешеннән дә күбрәк урын биләргә тиеш булмый. Шәһәр үзидарәсенең барлык органнары эшчәнлеге губернатор күзәтчелегенә буйсындырыла. Ш.д. аның алдында үз эшчәнлеге хакында хисап тота, шәһәр бюджеты фәкать губернатор рөхсәте б-н генә чыгымнарга тотыла. Гамәлдә Ш.д. салымнар җыю һәм аларны шәһәрнең хуҗалык ихтыяҗларына сарыф итү б-н шөгыльләнә. Казан губернасында шәһәр думалары Казанда, Козьмодемьянскида, Мариинск Посадында, (1856 дан), Зөядә, Чабаксарда, Чистайда, Царёвококшайскида, Цивильскида, Ядринда эшли (Арчада, Спасста һәм Тәтештә шәһәр думалары Павел I нең 1796 ел 31 декабрь Указы б-н бетерелә). Зур булмаган шәһәрләрдә Ш.д. урынына шәһәр башлыгы канцелярияләре (Алабугада, Царёвосанчурскида, Яранскида) һәм шәһәр ратушалары (Арчада, Лаешта, Мамадышта, Спаста, Тәтештә, Троицк Посадында) оештырыла.

1870 тәге шәһәр реформасы шәһәр үзидарәсенең сословиеле органнарын гомумсословиеле органнар — Ш.д. (боеручы) һәм Шәһәр идарәсе (башкарма) б-н алыштыра. Ш.д. 4 елга сайланган гласныйлардан тора. Сайлау хокукына 25 яшькә җиткән һәм шәһәр файдасына салымнар, җыемнар түләгән ир-атлар ия була. Хосусый затлар б-н бергә сайлау хокукы шәһәр бюджетына җыемнар түләгән ведомстволарга, учреждениеләргә, җәмгыятьләргә, ширкәтләргә, чиркәүләргә һәм монастырьларга да бирелә. Өч разрядлы сайлау системасы күздә тотыла; сайлаучылар шәһәр салымнарын түләүләрнең тигез гомуми суммалары тәгаенләнгән 3 куриягә (эре, уртача һәм вак салым түләүчеләр) бүленә. Һәр курия Ш.д. гласныйлары составының 1/3 өлешен сайлый. Сайлаучы вәкилләрнең (выборщикларның) аларны үз араларыннан да, башка разрядлардан да сайлау хокукы була. Гласныйлар шарлар салу юлы б-н ябык тавыш биреп сайланалар. Думаның составы, халык саныннан чыгып, 30 дан 72 гласныйга кадәр билгеләнә. Гласныйлардан утырышларда мәҗбүри катнашу таләп ителми, утырышлар саны тәгаен тотрыклы булмый. Шәһәр үзидарә органнарының адм.-хуҗалык вазифаларына шәһәрне төзекләндерү (яктырту, җылыту, су б-н тәэмин итү, чистарту, транспорт, шәһәр юллары, яр буйлары, күперләр), халык мәгарифе, сәламәтлек саклау, җәмәгать химаячелеге, сәүдә, сәнәгать үсеше турында кайгырту һ.б. керә. Бирелгән вәкаләтләре чикләрендә үзидарә органнары чагыштырмача бәйсез һәм мөстәкыйль булалар. Ш.д.на сословие эшләре йөкләнми һәм сословиеле учреждениеләр аңа буйсынмый. Шәһәр бюджеты күчемсез милектән алынган салымнар һәм җыемнар, шәһәр милкеннән (сәүдә рәтләре, мунчалар, шәһәрдәге сугым урыннары һ.б.) файдаланудан керемнәр, үлчәүләрне һәм үлчәү берәмлекләрен келәймәләүдән, аукционнардан кергән пошлина җыемнары һ.б., ш.у. дәүләт казнасыннан җибәрелгән акча нигезендә формалаша. Ш.д. мөстәкыйль рәвештә яңа салымнар кертә, салымнарның законда каралган нормасын арттыра алмый. Яңа нигезләмә буенча Ш.д. үз составыннан шәһәр башлыгын, аның иптәшен (урынбасарын), идарә әгъзаларын сайлый. Шәһәр башлыгы думаны һәм идарәне җитәкли, аларның эшен координацияли. Идарәнең төрле бүлекләрдән торган даими канцеляриясе эшли. Идарә әгъзаларының исәбен Ш.д. билгели, ләкин аларның саны, шәһәр башлыгын санамаганда, ике кешедән ким булмаска тиеш була. Шәһәр башлыгы вазифасында губерна шәһәрләрендә — эчке эшләр министры, башка шәһәрләрдә губернатор раслый. Идарә әгъзалары һәм секретарь вазифаларында раслау думаларның үз карамагында кала. Идарәнең христиан булмаган әгъзалары саны аның составының өчтән бер өлешеннән артмаска тиеш була. Һәр ике ел саен идарә әгъзаларының яртысы аның составыннан чыга һәм яңадан сайланган әгъзалар б-н алыштырыла. Зур булмаган шәһәрләрдә идарә вазифалары шәхсән шәһәр башлыгына

йөкләнә алган. Идарә әгъзалары Казанда — 6, Чабаксарда — 3, башка шәһәрләрдә икешәр кеше була. Идарә әгъзаларының күпчелеген мещаннар катлавы вәкилләре тәшкил итә. Шәһәр үзидарәсе эшчәнлегендә законнар саклануын губернатор рәислегендәге шәһәр эшләре буенча губерна кабулханәсе күзәтчелек итә. Яңа шәһәр нигезләмәсе 1892 нең 11 июнендә кабул ителә. Салым цензы милек цензы б-н алыштырыла, нәтиҗәдә, сайлауларда катнашырга рөхсәт ителгән затларның саны кими. Сайлау хокукы шәһәр сызыгы эчендә аеруча эре күчемсез милек биләгән хосусый затларга һәм учреждениеләргә бирелә (башкалаларда һәм халкы 100 мең кешедән арткан шәһәрләрдә күчемсез милек 3 мең сумнан да ким булмаган, губерна шәһәрләрендә 1–1,5 мең сум, өяз шәһәрләрендә аларда тәгаен күпме кеше яшәүдән чыгып, 300 сум чамасы күләмдә бәяләнергә тиеш). Христиан булмаган гласныйлар Ш.д. составының биштән бер өлешеннән дә артмаска тиеш була. Сайлаучылар исәбенә 1 нче һәм 2 нче гильдия сәүдәгәр таныклыклары булган сәүдә-сәнәгать пр-тиеләре хуҗалары кертелә. Аз һәм уртача күләмдә салым түләүчеләр сайлау хокукларыннан мәхрүм ителә, өч разрядлы система бетерелә. Ш.д.ндагы гласныйларның миним. саны 20 кешегә кадәр кыскартыла. 1870 тәге Шәһәр нигезләмәсе б-н чагыштырганда шәһәр үзидарәсе органнарының хокуклары һәм бәйсезлеге шактый чикләнә. Ш.д.ның мөһимрәк карарлары земство һәм шәһәр эшләре буенча губерна кабулханәсе тарафыннан расланырга тиеш була. Шәһәр идарәләренең җирле администрациягә бәйлелеге көчәя; барлык җитәкче составны, ягъни шәһәр башлыгын, аның иптәшен (урынбасарын), шәһәр секретарен, идарә әгъзаларын — администрация, башкалаларның шәһәр башлыкларына кандидатларны император раслый. Яңа нигезләмә буенча губернаторга Ш.д.ның карарларын гамәлдән чыгару хокукы бирелә. Шәһәр башлыгының думаларда һәм идарәләрдә җитәкчелеге саклана. Кечкенә шәһәрләр өчен яңа нигезләмә «гадиләштерелгән идарә» кертә. Йорт хуҗалары җыены — вәкаләтлеләр җыелышын (12– 16 кеше), вәкаләтлеләр шәһәр старостасын һәм аның 1–2 ярдәмчесен сайлый. Беркадәр үзгәрешләр б-н әлеге система Вакытлы хөкүмәт тарафыннан «Шәһәрләрдә җәмәгать идарәсе турында гамәлдәге нигезләмәләрне үзгәртү хакында» 1917 ел 9 июнь карары кабул ителгәнче яшәп килә. Ш.у.к. *Казан шәһәр думасы*.

*Әд.:* М и х а й л о в с к и й А.Г. Реформа городского самоуправления в России. М., 1908; Г р и г о р ь е в В. Реформа местного управления при Екатерине II. М., 1910; Н а р д о в а В.А. Городское самоуправление в России в 60-х — нач. 90-х гг. XIX в. Л., 1984; З о р и н А.Н. Горожане Среднего Поволжья во второй половине XVI — начале XX вв.: Историко-этногр. очерк. К., 1992; ш у л у к. Города и посады дореволюционного Поволжья. К., 2001.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ШӘҺӘ́Р КАРДИОЛО́ГИЯ ДИСПАНСЕРЫ́**, к. *Диспансерлар*.

**ШӘҺӘ́Р МЕДИЦИ́НА ЯРДӘМӘ́ КҮРСӘТҮ́ СТА́НЦИЯСЕ**, к. *Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү хезмәте*.

**ШӘҺӘ́Р, РАЙО́Н-ШӘҺӘ́Р, РАЙО́Н ГАЗЕ́ТАЛАРЫ**, шәһәр һәм район хакимиятләре вакытлы басмалары. 1920 еллар ахырыннан совет матбугаты басмаларының яңа типлары хисабына үсә. Бу вакыттан урыннардагы массакүләм матбугат киң тарала башлый. 1930 ның 11 августында ВКП(б) ҮК округларны бетереп, районнар оештыру, бер үк вакытта җирле матбугат челтәрен үзгәртеп кору турында карар кабул итә. Округ, колхоз-совхоз һәм завод-фабрикалар газеталары җирлегендә район һәм шәһәр матбугаты оеша башлый, ул җирле социаль-икътисади, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышны яктыртырга тиеш була. Татарстандагы беренче район газеталары 1930 дан җирле партия һәм совет органнары басмалары буларак нәшер ителә. Район халкын тулысынча колачлар өчен газеталар милли составка бәйле рәвештә рус, татар, чуаш, удмурт телләрендә кабатлана. Район үзәге шәһәр булган районнарда берләштерелгән район-шәһәр газеталары — район һәм шәһәр хакимиятләре органнарының уртак басмалары нәшер ителә. 1931 дә Татарстанда — 37, 1932 дә 41 район һәм шәһәр газеталары була. Алга таба район газеталары саны респ-каның адм.-терр. бүленешенә карап үзгәрә. ВКП(б) ҮКның «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» карары нигезендә (1944) ТАССРның яңа оешкан районнарында (Әгерҗе, Буа, Чүпрәле, Кукмара, Тәкәнеш, Шөгер, Ютазы) район газеталары чыгарырга рөхсәт бирелә. 1960 елларның 1 нче яртыеллыгында, районнарны эреләндерү кампаниясе чорында, терр.-җитештерү идарәләренең районара газеталары басыла. Татарстандагы беренче шәһәр газетасы — «Вечерняя Казань», ул 1979 дан нәшер ителә; аннары Казанда башка шәһәр газеталары — татар телендә «*Шәһри Казан*» (1990), рус телендә «Казанские ведомости» (1991) дөнья күрә башлый.

1930 елларда Татарстаннан читтә татарлар тупланып яшәгән районнарда да ш.у. татар телендә район газеталары чыга башлый, аларның күбесе соңрак ябыла. 20 йөз ахырына кайберләре генә сакланып кала: «Күмәк көч» (Ульянов өлкәсе Иске Кулаткы р-ны), «Таң» (Пермь өлкәсе Барда р-ны) һ.б. БРда татар телендә 26 район һәм район-шәһәр, 2 шәһәр газетасы басыла.

1991 нең августыннан газеталар Халык депутатлары советлары башкарма ком-тлары, 1994 тән район һәм шәһәр хакимиятләре тарафыннан чыгарыла башлый. 1990 да кайбер газеталарның исеме үзгәртелә, дубляж газеталарның бер өлеше мөстәкыйль басмаларга әверелә. Бу чорда 1930 еллар традициясе буенча (1932–35 тә — Казанның Шәһәр Бистәсе р-нының «Большевиклар темпы өчен» — «За большевистские темпы», 1932–37 дә Ленин р-нының «Советлар канаты» — « Крылья Советов», 1933 тә — Сталин р-нының «Икенче бишьеллык өчен» — «За вторую пятилетку» г-тасы чыга) Казанда район газеталары — «Мәскәү районы» («Московский район»), «Идел буе районы» («Приволжский район»), «Совет районы панорамасы» («Панорама Советского района») басыла. 2010 ның 1 гыйнварына ТР да 57 шәһәр, район-шәһәр, район газетасы татар, рус, чуаш һәм удмурт телләрендә нәшер ителә.

Чыг.: Печать, радиовещание и телевидение Татарии. 1917–1980: Сб. док. и материалов. К., 1981.

*Әд.:* Л о г а ч ё в а А.К. Роль периодической печати в борьбе партийной организации Татарии за социалистическую индустриализацию республики (1926–1932): Дис. ... К., 1975.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ШӘҺӘ́Р ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Чистай шәһәрендә, 1921 елның 8 апрелендә төбәкне өйрәнүче, натуралист А.К.Булич башлангычы б-н аның шәхси коллекцияләре нигезендә ачыла. 1982–2006 да, Чистай өяз каласы музее буларак, ТР Милли музее ф-лы; 2007 дән муниципаль музей. 2014 тән хәзерге исемдә, Чистай дәүләт тарих-архит-ра һәм әдәби музей-саклаулыгы составында. Экспозиция мәйданы — 508 *м*², коллекцияләрендә 31 меңгә якын саклау берәмлеге исәпләнә. Сәүдәгәр И.Г.Стахеевның соңыннан кызы Мариягә (сәүдәгәр А.А.Подураевка кияүгә чыга) бүләк иткән йортында урнашкан (19 йөз ахыры; архит-ра истәлеге). 2003 тән реконструкцияләнә, вакытлы күргәзмәләр экспозициягә куела. Музей тупланмасында палеонтологик, археол., табигыять-фәнни коллекцияләр: борынгы болгар көбәсе, сфероконус рәвешендәге савыт, мамонт, бизон, мөгезборын калдыклары һ.б., Чистай р-ны терр-ясендә очраучы кошлар йомыркалары һәм сөкәтләре коллекцияләре бар. 17–20 йөзләр язма чыганаклар коллекцияләре арасында — «Чиркәү җыр йоласы» («Церковный певчий обиход»), «Ирмослар» («Ирмосы»), «Җырлау яңгырашы» («Трезвон певчий»), «Изгеләр тормышы» («Жития святых») (барысы да — 17 йөз), «Инҗил» («Евангелие», 1856) һ.б. Этнография тупланмасында Урта Идел буенда яшәүче рус, татар, чуаш халыкларының көнкүреш әйберләре, милли костюмнары, бизәнү әйберләре, хезмәт кораллары, һөнәрчелек эшләнмәләре бар. Музейга шәһәрнең танылган кешеләренең, ш. у. 1941 нең көзеннән 1943 нең июненә кадәр Чистай шәһәренә эвакуацияләнгән совет язучылары Н.Н.Асеев, В.Ф.Боков, В.С.Гроссман, Б.Л.Пастернак, И.Л.Сельвинский, К.А. һәм Л.М.Тренёвлар һ.б.ның документлары, фоторәсемнәре, шәхси әйберләре куелган. Шәһәр көнкүреш әйберләре коллекциясендә (йорт җиһазы, фарфор, декоратив тукымалар һ.б.) 1902 дә һәм 1909 да Чистай Выселкасы авылы крәстияне Н.И.Мельников ясаган 2 агач велосипед бик кызыклы. Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында — документлар һәм сирәк китаплар (7270 берәмлек), этнография (982 берәмлек) һәм техника тарихы (2 берәмлек) әйберләре, нумизматика (5383 берәмлек). Музей ел саен ачылу көнен, музейга нигез салучы һәм аның беренче директоры А.К.Буличның туган көнен (13 апр.), Халыкара музейлар көнен билгеләп уза.

*Әд.:* Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999; Российская музейная энциклопедия. М., 2001. Т. 2.




Ш ә һ ә р  т ө з е л е ш е.  10  й ө з – 13  й ө з  б а ш ы  И д е л  б у е  Б о л г а р  д ә ү л ә т е  ш ә һ ә р л ә р е.

**Биләр** (1). 1973 елгы аэрофоторәсем материаллары буенча шәһәрнең схематик планы (Ф.Ш.Хуҗин планы нигезендә Х.Г.Надыйрова реконструкциясе). Планга экспликация: 1 — Җамигъ мәчет; 2 — Җамигъ мәчет белән комплекстагы таш бина; 3 — мунча; 4 — базар мәйданындагы мәчет; 5 — металл коючылар бистәсе; 6 — кәрван-сарайдагы мунча; 7–11 — һөнәрчеләр бистәләре; 12–16 — мөселман зиратлары; 17 — шәһәр яны бистәләре; 18–26 — шәһәргә керүче төп юллар; 27 — юрта урнашкан җир; 28 — хәзерге торулык территориясе.

**Суар** (2), **Ашлы** (3), **Җүкәтау** (4) шәһәрләренең археологик мәгълүматлар буенча схематик планнары. Планнарга гомуми экспликация: 1 — шәһәр; 2 — урлардан һәм ерымнардан торган саклану системасы; 3 — посадлар; 4 — мөселман зиратлары; 5 — таш бина хәрабәләре; 6 — шәһәрнең саклану диварлы хисары (цитадель); 7 — юллар; 8 — чокырлар; 9 — инеш.




Алтын Урданың Болгар олысындагы шәһәр төзелеше. **Болгар ш.** 14 йөз уртасы. Ф.Ш. Хуҗин материаллары буенча схематик план. 1. Җамигъ мәчет; 2. Төньяк төрбә; 3. Көнчыгыш төрбә; 4. Көнчыгыш пулат (мунча); 5. Кызыл пулат (мунча); 6. Ак пулат (мунча); 7. Кара пулат; 8. Хан төрбәсе; 9. Шәһәрнең монголларгача кадәрге чордагы саклану диварлары урыны; 10. Төрбә; 11. Мунча; 12. Кече манара; 13. Әрмән бистәсендәге Грек пулаты (храм); 14. Кирпеч-таш корылмалар хәрабәләре; 15. Кече шәһәрчек; 16. Урдан һәм ерымнан торган саклану системасы; 17. Түбәнге посад һәм Рус бистәсе; 18. Шәһәрнең төньяк чиге; 19. Зират; 20. Әрмән бистәсе.

Казан ханлыгының 15 йөздәге – 16 йөзнең 1 нче яртысындагы шәһәрләре. **Казан** (2). А.Сацыперовның 1730 еллардагы планы нигезендә шәһәрнең планировка структурасы (Х.Г.Надыйрова реконструкциясе). Ханлык чоры Казаны планына экспликация: I. Ак таш диварлары, манаралары һәм сулы ерымы булган кирмән: А — хан ишегалды (1 — үтү манарасы, 2 — Хан сарае, 3 — Хан мәчете, 4 — ике хан төрбәсе); Б — кирмән хисары (цитадель) (5 — Колшәриф мәчете һәм мәдрәсәсе, 6 — беренче саклану сызыгының үтеп йөрү манарасы, 7 — Нургали мәчете, 8 — 13–16 йөзләрдәге ак таш дивар); 9 — фаразланганча, икенче саклану сызыгының үтеп йөрү манарасы; 10 — урамнар; 11 — манаралар: 12 — Нургали, 13 — Алабуга, 14 — Сбойливый (татарча исеме билгесез), 15 — исемсез, 16 — Хан, 17 — Төмән, 18 — «Яшерен чишмә» манаралары; 19 — Таһир мунчасы; 20 — ерым; 21 — Черек күл. II. Манаралы агач диварлар белән әйләндереп алынган Казан посады: 22 — Үтеп йөрү, 23 — исемсез, капкасыз, 24 — Кайбат, 25 — Арча, 26 — Патша, 27 — Югары Нугай, 28 — Түбән Нугай, 29 — Аталык манаралары; 30 — Ак күл; 31 — Кара күл; 32 — посад диварларының төньяк-көнбатыш өлеше урнашуы ихтимал урын; 33 — Күрәеш бистәсе; 34 — Казанның әүвәлге посадлары; 35 — исемсез бистәләр. **Арча** (кирмән-кала) (3), **Иске Казан** (4), **Чаллы** (5) шәһәрләренең схематик планнары (Н.Ф.Калинин материаллары буенча).









17 йөздә Казан төбәгендә шәһәр төзелеше. 1. **Казан**. Шәһәрнең төньяк тарафтан күренеше. Н.Витсен манзарасы. 17 йөз ахыры; 2. 17 йөз ахырындагы Казанның планлаштыру схемасы (А.Сацыперов планы нигезендә Х.Г.Надыйрова реконструкциясе). Схемага экспликация. Агач посадның: 1 — яшерен (үтеп йөрүле), 2 — Ярославль, 3 — Сигез почмаклы, 4 — «Болак артындагы», 5 — Сигез почмаклы, 6 — Илья (Мокрый, үтеп йөрүле), 7 — Алты почмаклы, 8 — Ям (үтеп йөрүле), 9 — Алты почмаклы, 10 — Варлам (үтеп йөрүле), 11 — Алты почмаклы, 12 — Богоявление-Калитошный, 13 — Проломный, 14–16 — Алты почмаклылар, 17 — Воскресение (үтеп йөрүле), 18 — Арча (үтеп йөрүле), 19 — Сигез почмаклы, 20–24 — Алты почмаклылар, 25 — Пятницкий (үтеп йөрүле) манаралары. Акташ Кремльнең үтеп йөрүле: 26 — Спас, 27 — Димитр, 28 — Воскресение, 29 — Никола (хәзер Яшерен), 30 — Преображение манаралары. 3. 17 йөз ахырындагы **Лаеш** кирмән-каласы (И.В.Назарова реконструкциясе).
























18 йөзнең 1 нче яртысында Казан губернасында шәһәр төзелеше. 1. **Казан**. Шәһәрнең үзәк өлешенең төньяк тарафтан күренеше. А.И.Свечин рәсеме. 1763 (64) ел; 2. **Казан**. А.Сацыперов планы. 1730 еллар.
1789 елгы «Казан наместниклыгы шәһәрләре атласы» һәм 1796 елгы «Казан губернасының геометрик картасы» буенча **Арча** (3), **Зөя** (4), **Чистай** (5), **Лаеш** (6), **Мамадыш** (7), **Тәтеш** (8) шәһәрләренең планлаштыру схемалары.



















Шәһәрләрнең даими планнары. 18 йөзнең 60 еллары ахыры – 19 йөзнең 20 еллары. 1. **Казан**. 1768. Архитектор В.И.Кафтырев; 2. **Тәтеш**. 1822; 3. **Лаеш**. 1822; 4. **Зөя**. 1829; 5. **Алабуга**. 1829; 6. **Чистай**. 1829.










Татарстан Республикасының хәзерге шәһәрләре. 1. Казан территориясен файдалану планы. 2004. Эшләүчесе — «Казгражданпроект»; 2. Түбән Кама шәһәре территориясен файдалану схемасы. Түбән Кама шәһәренең генераль планы. 2004. Эшләүчесе — «Татинвестгражданпроект»; 3. Чаллы шәһәренең генераль планы концепциясе (1 нче вариант). 2004. Эшләүчесе — «Татинвестгражданпроект».

**ШӘҺӘ́Р ТӨЗЕЛЕШЕ́**. Татарстан терр-ясендә 10 йөздән Идел буе Болгар дәүләтендә үсеш ала. Андагы адм.-терр. бүленеш һәм урнашу тәртибе борынгы феодаль дәүләттәге кабилә структурасына нигезләнә. Урнашкан терр-яләрендә болгар кабиләләре берләшмәләренең үз үзәкләре — шәһәрләр була. Аларның иң эреләре — Биләр һәм Болгар — төрле этапларда дәүләтнең башкалалары да булып тора. Идел буе Болгар дәүләтенең күп кенә шәһәр-кальгалары һәм авыллары (ныгытылмаган торулыклар) аның чикләрендә һәм мөһим сәүдә юлларында урнаша (20 дән артык шәһәр, 100 шәһәрлек һәм 800 авыллык урыны ачыклана). 10 — 13 йөзләр рус елъязмаларында Биләр һәм Болгардан башка Тухчин, Торцк, Бряхимов (Ибраһим), Ашлы, Сабакүл, Чылмата һ.б. шәһәрләр дә искә алына. Идел буе Болгар дәүләтенең күпчелек шәһәрләре елгалар, тирән ерымнар чыгынты ясап кушылган биек калкулыкларда төзелә. Табигый каршылыклар б-н сакланмаган тарафы 2 — 3 рәт ур һәм чокыр б-н ныгытыла. Идел буе Болгар дәүләтенең монгол яуларына кадәрге башкаласы Биләр шәһәре 10 йөздә тигез ачык урында төзелә һәм икешәр рәт ур, чокыр һәм каравыл манарасы булган агач дивар б-н әйләндереп алына. Шәһәрнең үзәген Җамигъ мәчет тәшкил итә. Биләрдә кәрвансарай, мунчалар, хан сарае һәм аксөякләрнең йортлары, гади халык торакларының (башлыча агачтан) калдыклары табыла. Дәүләтнең эре шәһәрләреннән берсе Суар була. Аның урнашу рәвеше, конфигурациясе, саклану корылмалары системасы Биләр б-н охшаш. Шәһәр үзәгендә кирпеч мунча калдыклары табыла. Очлаеп килгән калкулыкка урнашкан Җукәтау шәһәренең кыр ягы өч рәт ур, ике рәт чокыр б-н әйләндереп алынган һәм аның күпләгән бистәләре булган; эре шәһәрләрдән янә берсе — Идел алдындагы Ашлы — ныгытмалар һәм бистәләр б-н көчәйтелгән. Монгол яулары вакытында Идел буе Болгар дәүләтенең Биләр һәм башка күп кенә шәһәрләре, авыллары тулысынча диярлек җимерелә; аларның кайберләре соңрак кабат торгызыла һәм яңа шартларда күтәрелеп китә. Олысның башкаласы Болгар була һәм ул берникадәр вакыт Батый хан станы вазифасын үти. Бу чорда шәһәрнең терр-ясе берничә тапкыр зурая; 13 йөз ахырында — 14 йөзнең 1 нче яртысында анда монументаль таш биналар (мәчетләр, мунчалар, төрбәләр, сарайлар, кәрвансарайлар) күпкә арта. Идел-Кама буенда беренче буларак, шәһәр уртасындагы таш түшәлгән мәйданы б-н *Болгар Җамигъ мәчете* архит-ра ансамбле оеша. Таш түшәлмә һәм фонтан калдыклары зур җәмәгать мунчалары фасадлары алдында да табыла. Археол. материалларыннан күренгәнчә, кайбер урамнарда агач тротуарлар булган; агачтан торак йортлар, һөнәрче остаханәләре төзелгән. Шәһәрнең төньяк-көнбатыш читендә таштан салынган чиркәүле әрмән колониясе, төньякта, елга аръягы өлешендә, рус бистәсе урнашкан була. Төньяк-көнбатышка таба 6 *км* ераклыкта, Идел елгасы ярында Болгарның пристане һәм сәүдә-йөк күчереп төяү базасы — *Ага базар* эшли. 14 йөзнең 2 нче яртысында Алтын Урда ханнары хакимлеге йомшау сәбәпле, шәһәрләр тирәсендә саклану корылмалары төзелә башлый. Олыс башкаласы манзарасын урлар өстендәге агач кирмән диварлары, Шәрекъ-мөселман типологиясендәге монументаль кирпеч-таш биналар, гадәти агач корылмалар хасил итә. 1361 елда шәһәрнең Булат Тимер гаскәрләре тарафыннан яулап алынуы Болгарны сизелерлек көчсезләндерә, ә 1431 дә аны Василий Пёстрый җитәкчелегендәге рус гаскәрләре тар-мар иткәннән соң, дәүләтчелек үзәге роле Казанга күчә. 15 йөзнең 1 нче яртысында Алтын Урданың Болгар олысы аерым бәклекләргә бүленә, халыкның урнашу системасы төбәкнең төньягында яңа шәһәрләр һәм авыллар барлыкка килү хисабына киңәя. Элекке Болгар олысы шәһәрләренең һәм авылларының күпчелеге әле берникадәр вакыт яши, ләкин көньяк далалардагы күчмә кабиләләрнең даими һөҗүм итеп торулары нәтиҗәсендә элекке статусын, әһәмиятен һәм биләмәсен югалта. 15 йөз уртасында оешкан Казан ханлыгы чорында терр-я бүленешендә яңа адм. округлар — даругалар барлыкка килә. Алат, Арча, Галич, Җөри һәм Нугай даругаларының үз үзәк шәһәрләре була. Казан ханлыгы чорында кайбер Болгар чоры чик буе кальгалары шәһәрләргә әверелә (Казан, Арча, Чаллы шәһәрчеге). Урта гасырлар чоры Көнчыгыш Европа Ш.т. системасында Идел-Кама буе шәһәрләре мөһим урын тота. Аларның аеруча танылганнары Көнчыгыш Европаның Көнбатыш Европа картографлары тарафыннан сызылган күп кенә карталарында билгеләнгән. Төбәкнең аерым геосәяси әһәмияткә ия булуы, анда, җирле традицияләр б-н беррәттән, үзара йогынты кичереп, Алтын Урда һәм Рус дәүләте Ш.т. традицияләре дә яшәү өчен үзенчәлекле буфер зонага әверелүенә китерә. Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы башкалалары төзелешенә өч өлешле структура хас була: кайсар (цитадель, хакимнең ныгытылган сарае), капкалы манаралар аша үтүче юллар б-н тоташкан «эчке шәһәр»-кирмән һәм «тышкы шәһәр» (гадәттә, кирмәннән чокырлар, урлар, манаралы диварлар б-н аерылып торган бистә). Казанда кайсар ролен хан сарае үтәгән. Ул калын диварлар б-н ныгытылган, көнбатыш, көнчыгыш һәм көньяк тарафлардан ш.у. диварлар эчендәге бистәләр б-н әйләндереп алынган кирмәннең бер өлешен хасил иткән. Кирмән эчендә таш мәчетләр, төрбәләр, мунчалар һ.б. монументаль һәм җәмәгать корылмалары урнашкан, бистәдә йортлар агачтан салынган. Арча, Иске Казан, Чаллы һ.б. шәһәр-кирмәннәр чокырлар, урлар һәм каравыл манаралары булган диварлар б-н ныгытылган.

16 йөз уртасында Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яулап алынганнан соң, Идел-Кама буенда Ш.т. тамырдан үзгәреш кичерә. Төбәктә өяз адм. структурасы кертелә. Бәклек шәһәрләре — даруга үзәкләре, яңа шартларда үзләренең әһәмиятләрен югалта, кайберләре рус кальгалары итеп үзгәртелә (төбәкне колонияләштерүне һәм христианлаштыруны тәэмин итү үзәкләренә әвереләләр), икенчеләре, сәүдә-базар функциясенә күчеп, халкы аз булган төбәккә әйләнәләр яки бөтенләй бушап калалар. Кайбер татар шәһәрләре (Алат, Җөри, Мәңгәр һ.б.) сәүдә-һөнәрчелек үзәкләре ролен саклап калалар. Кама аръягындагы Болгар, Җукәтау һ.б. шәһәрләр күчмә халыкларның һөҗүмнәре нәтиҗәсендә бушап кала. Рус Ш.т. традициясе төбәктә, аеруча буш урыннарда яңа шәһәрләр төзүдә — Зөя (1551), Лаеш (1557), Зәй (1652 — 56), ш.у. тарихи үткәне булган шәһәрләрдә һәм авылларда — Тәтеш (1578), Минзәлә (1584–86), Арча (1606) — чагылыш таба. Казан тамырдан үзгәртелә, 16 йөз ахырында ул рус шәһәре рәвеше ала башлый. Татар аксөякләре сарайлары, мәчетләр юкка чыгарыла яки үзгәртеп корыла. Төбәк халкының урнашуында да тамырдан үзгәрешләр була: шәһәрләрдән, ш.и. Казаннан татарлар куып чыгарыла, шәһәр читендә татар бистәләре оеша. Идел һәм Кама буендагы авылларга Рус дәүләтенең төрле өлкәләреннән руслар китереп утыртыла. 17 йөздә Кама аръягы *чик буе киртәләрен* төзү барышында рус һәм башка халыкларның күпләгән авыллары барлыкка килә. Кирмән-шәһәрләр б-н бергә Казан тирәсендә һәм рус булмаган халыкларны интенсив христианлаштыру барган төбәкләрдә православие монастырьлары — Семиозёрка авылында Богородица ирләр монастыре, *Раифа Богородица пустыне* төзелә. Көнчыгыш Европа Ш.т. б-н уртак булган системаның электән килә торган иерархиясе саклана: эре шәһәрләр — хакимият-икътисад үзәкләре, чик буе шәһәр-кирмәннәре, сәүдә-һөнәрчелек шәһәр һәм бистәләре, авыллар. 18 йөз башында күчмә халыклар һөҗүме куркынычы кимегәч һәм Россия дәүләтенең чикләре киңәйгәч, Казанда һәм Зөядә кирмән диварлары сүтелә, чокырлар күмелә; кирмән (кремль) бары тик Казанда гына сакланып кала, андагы бистә диварлары 1729 да сүтелә. Төбәк шәһәрләрендә урам планнарының бердәм — даими булмаган төре урнаша. 18 йөздәге эчке чикләрнең бүленеше, Казан наместниклыгы, аннары Казан губернасы оешу урнашу тәртибенең электән килгән системасында үзгәрешләр барлыкка китерә: төбәкнең күпчелек өлеше Казан губернасы, төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш өлешләре Вятка һәм Уфа губерналарына кертелә. Төбәкнең торак пунктлары типологиясен губерна шәһәре Казан, өяз шәһәрләре Минзәлә, Лаеш, Чистай, Зөя, Спас, Мамадыш, Тәтеш, Буа, Бөгелмә; штаттан тыш шәһәр Арча; авыл җирлекләре — бистәләр, халкының төп шөгыле сәүдә һәм җир эшкәртү булган авыллар барлыкка китерә. Шәһәр итеп «билгеләнгән» җирлекләр (Чистай, Бөгелмә), ш.у. кайбер кальга-шәһәрләр (Лаеш, Арча, Тәтеш) зурлыклары б-н эре сәүдә-һөнәрчелек авылларыннан аерылмый диярлек. Татар авылларының архит-ра-фәзаи ягыннан оешуында милли үзенчәлекләр күзәтелә (бормалы ябык урамнар, манаралы берничә мәчет, йорт корылмалары төсле бизәлешле иерархик хуҗалыклар). Аларның бер өлешен халык саны һәм төзелеше ягыннан тулы мәгънәсендә кече шәһәрләр рәтенә кертергә мөмкин (Алат, Җөри, Түнтәр, Олы Мәңгәр, Олы Әтнә, Байлар Сабасы һ.б. авыллар).

18 йөзнең 2 нче яртысында Екатерина II нең «Барлык шәһәрләргә, аларның төзеле-

ше һәм урамнарына һәм губерна буенча аерым махсус планнар эшләү турында» («О делании всем городам, их строению и улицам специальных планов по каждой губернии отдельно», 1763) Фәрманы нигезендә Казан губернасында шәһәр төзелешен тәртипкә китерү, махсус закон буенча шәһәрләрнең регуляр планнарын эшләү башлана. Россия империясенең Законнар җыелмасындагы Төзелеш уставы шәһәрләрнең үсеш шартларын һәм алардагы төзелеш кагыйдәләрен билгеләде. Шәһәрләрнең ген. планнарын эшләү өчен Казан губернасында беренче тапкыр проф. архитекторлар җәлеп ителә, Казан губернасы архитекторы, Казан губернасы инженеры һәм җир үлчәүчесе вазифалары кертелә. Казан губернасы идарәсендә Казан губерна сызым (1779–1918) һәм Казан губерна төзелеш (1816–46) комиссияләре оештырыла. Казан губерна сызым комиссиясе тарафыннан өяз планнары, ызан кенәгәләре, шәһәрләрнең гамәлдәге һәм үзгәртеп кору планнары, күперләрнең, шәһәрчекләрнең сызымнары, өяз җир үлчәүчеләренең рапортлары, кыр журналлары һ.б. эшләнә һәм саклана, губернадагы шәһәрләрдә һәм өязләрдә җир һәм утар үлчәмнәренең үзгәрешләре теркәп барыла. Эчке эшләр министрлыгының Юллар һәм җәмәгать биналары баш идарәсенә караган төзелеш комиссиясе тарафыннан шәһәрләрдәге һәм авыллардагы йортларның, җәмәгать биналарының үлчәм һәм проект сызымнары ясала. Казан губернасы архитекторлары губерна төзелеш комиссиясе (1846 да Казан губерна төзелеш һәм юл эшләре комиссиясенә, 1865 тә Казан губерна идарәсенең төзелеш бүлегенә үзгәртелә) әгъзалары булып тора. 18 һәм 19 йөзләрдә төбәк шәһәрләрен һәм авылларын даимилек принцибында үзгәртеп кору эшләре Казан, өяз шәһәрләре һәм кече шәһәрләр (18 йөз ахыры – 19 йөзнең беренче чиреге, Петербург һәм Казан архитекторлары), зур авыллар (1860–70 еллар) өчен аерым ясалган план нигезендә алып барыла. Шәһәр-авылларны яңа планнар нигезендә даими тәртипкә китерү күп дистә еллар буена шәһәрләр үсешенең ген. планын тәшкил итә. Бу планнар нигезендә шәһәр һәм авыл урамнары турыпочмаклы челтәр хасил итеп турайтыла, периметр буенча һәм эчтә төзелгән кварталлар хисабына эреләндерелә. Чиркәүләре һәм җәмәгать биналары булган мәйданнар барлыкка килә. Шәһәр читләрендә заводлар, фабрикалар, гади халык яши торган бистәләр урнаша.

Үзәк кварталлар читендә тоташтан күп катлы йортлар төзелү, кварталлар эченең яңа төзелешләр хисабына тыгызлануы, шәһәрнең үзәк өлешендәге яр буйларын, мәйданнарны һәм бакчаларны төзекләндерү 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башындагы Ш.т. үзенчәлеге булып тора. Үзенчәлекле архит-расы, очлы манаралары б-н татар бистәләре шәһәрләргә шәркый төсмер бирә. 20 йөз башына төбәктә халыкның күчеп утыру процессы акрыная. Шәһәрләр һәм эре торак пунктлар алдан әзерләгән план нигезендә үсә. Совет хакимияте вакытында Татарстанда *индустрияләштерү* сәясәтен гамәлгә ашыру уңае б-н урбанизация процессы көчәя, шәһәрдә халык саны тизлек б-н арта башлый. Шәһәрләрнең гасырлар дәвамында сакланып килгән татар һәм рус өлешләренә бүленеше сизелерлек рәвештә юкка чыга бара. 1926 да Казан Ш.т.нең яңа схемасы эшләнә (Ф.П.Гаврилов һәм архитекторлар төркеме; гамәлгә ашырылмый). 1930 еллардан башлап кайбер торак пунктлар шәһәрләргә әверелдерелә — Зеленодольск (1932, хәзер Яшел Үзән), Әгерҗе (1938). Бу вакытта Казан өчен 2 ген. план эшләнә (1933–34, Мәскәү «Гипрогор-2» ин-ты, җитәкчесе В.Н.Дмитриев; 1935–41, «Ленгипрогор» ин-ты, җитәкчесе И.С.Носов), ләкин аларның берсе дә ахыргача үтәлми. Бөек Ватан сугышы елларында проектлау-планлаштыру һәм илнең Көнбатыш өлкәләреннән эвакуацияләнгән сәнәгать пр-тиеләрен Татарстан терр-ясендә урнаштыру эшләре б-н Фәнни-техник совет (1944 тән башлап — ТАССР ХКС каршындагы Архит-ра эшләре идарәсе; бу идарә органнары турында к. *Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы*). Сугыш елларында Казанда эре сәнәгать пр-тиеләре урнаштырылу һәм Куйбышев ГЭСы төзелү б-н бәйле рәвештә «Ленгипрогор» ин-ты тарафыннан Казанның яңа планы һәм төзелешләре проекты эшләнә (1948–52, җитәкчесе И.С.Носов). Урамнарның радиаль-җилпәзә челтәрен саклаган хәлдә, ген. план кайбер магистральләр сузу, мәйданнар төзү, шәһәрне су басудан саклау инженерлык системасын оештыруны күз алдында тота. Сугыш вакытында һәм аннан соңгы елларда Казанда һәм башка шәһәрләрдә сәнәгать пр-тиеләре янындагы яңа терр-яләрне үзләштерүгә бәйләп, составында кибетләр, җәмәгать туклануы, сәламәтлек саклау, халык мәгарифе, мәдәни-агарту эшләре, спорт учреждениеләре булган соц. шәһәрчекләр проектлана һәм төзелә. Сугыштан соңгы елларда респ-каның нефть табыла торган көньяк-көнчыгыш районнары аеруча интенсив үсеш кичерә. Элекке торак пунктлар базасында Әлмәт (1953), Лениногорск (1955) шәһәрләре барлыкка килә.

СССР МС тарафыннан илдә Ш.т. сәясәтен үзгәртүдә мөһим роль уйнаган «Проектлауда һәм төзелештә артыклыкларны бетерү» (1955), «Алга таба индустрияләштерү, төзелешнең сыйфатын яхшырту һәм үзкыйммәтен киметү чаралары турында» (1955), «СССРда торак төзелешенең үсеше турында» (1957) карарлар кабул ителгәннән соң, шәһәрләр үсешендә яңа этап башлана. Шәһәрләрдәге буш урыннарда индустриаль алым б-н унификацияләнгән конструкцияләрдән эре торак микрорайоннар төзү башлана. 1960 елларда, химия сәнәгате үсешенә бәйле рәвештә Менделеев (1967), Түбән Кама (1969), 1970 елларда *КамАЗ* б-н бергә Чаллы шәһәрләре төзелә. Алар даими планлаштыру, алдан эшләнгән план нигезендә, сәнәгать, җәмәгать, торак һ.б. зоналарга төгәл бүленгән, биек торак йортлары булган кварталлар, заманча җәмәгать биналары: кинотеатр, мәдәният сарайлары, эре сәүдә үзәкләре һ.б. б-н бергә төзелә. 1969 да Казанның ген. планы («Ленгипрогор» ин-ты эшли); 1960–80 еллар башында беренче озак вакытка исәпләнелгән зур масштаблы шәһәр төзелеше документлары — Көньяк-Көнчыгыш, Чаллы, Казан сәнәгать р-ннарын районлап планлаштыру проектлары, 1974–92 дә Татарстанның күпчелек шәһәрләрен үстерүнең Ген. планы раслана. Шәһәр төзелешенә караган документлар арасында, ген. планнардан тыш, респ-ка шәһәрләре өчен шәһәр чиге проектлары, тәфсилле планлаштыру һәм төзелеш проектлары эшләнә һәм кулланыла башлый. Аларны эшләүдә илнең («Гипрогор», «ЦНИИП-Градостроительства», Мәскәү; «Ленгипрогор», «ЛенНИИПГрадостроительства») һәм Татарстанның («Татгражданпроект», «Казгражданпроект») әйдәп баручы проект ин-тлары катнаша. 1995 тә респ-када шәһәр төзелеше эшчәнлеген көйләү буенча төп законлаштырылган һәм норматив актларның берсе — ТРның Ш.т. кодексы кабул ителә. Тарихи-мәдәни мирасны саклау максатында шәһәрләрдәге тарихи үзәкләрне төзекләндерүгә аеруча зур игътибар бирелә (к. *Тузган торакны бетерү программасы*). 1990 еллардан башлап шәһәрләрнең архит-ра үзенчәлеген билгеләүдә гыйбадәтханәләр һәм уңайлык дәрәҗәсе югары булган торак йортлар төзү зур роль уйный башлый. Шәһәрнең яңа ген. планын эшләүгә керешелә («Казгражданпроект»): Казанның шәһәр төзелеше үсеше концепциясе раслана (1995), илдә беренче тапкыр Түбән Новгород, Казан, Тверь шәһәрләрендә Ш.т. сәясәтенең яңа документы — Ш.т. уставы гамәлгә кертелә (1998). Шуның буенча Казанда Төзелеш һәм Җирдән файдалану кагыйдәләре эшләнә. Бу документның нигезенә шәһәрне аның барлык терр-тиясендә Ш.т. сәясәтенең хокукый, дифференциациягә регламентын билгеләүче төзелеш зоналарына бүлү керә.

2002 дә шәһәр хакимияте җитәкчелеге тарафыннан Казанның Ген. планы концепциясенә заказлы конкурс уздырыла. Конкурста «Казгражданпроект» ин-тының һәм шәһәр төзелеше ЦНИиЭПның (Мәскәү) берләштерелгән иҗат коллективы җиңеп чыга, 2003 тә ул Ген. планны эшләүгә керешә. 2007 ел ахырында Казанның яңа Ген. планы проектын Казан шәһәр думасы раслый. Әмма шәһәрнең әлеге Ген. планын гамәлгә ашыру билгеле бер проблемалар б-н очраша. Беренчедән, 2005 нең гыйнварында РФнең яңа Ш.т. кодексы гамәлгә керә, ул аңа кадәр Ш.т. эшчәнлеген көйләп килгән норматив документлардан тамырдан аерыла. Икенчедән, шәһәр мәйданы, 180 *км*² шәһәр яны терр-яләрен кушу хисабына үзгәреп, 607 *км*² га җитә. Бу үзгәрешләр Ген. планны эшләү төгәлләнү чорында була, шуңа күрә яңа кушылган терр-яләр анда тиешле дәрәҗәдә эшләнеп бетми.

РФнең яңа Ш.т. кодексы барлыкка килү Россиядә Ш.т. эшчәнлегенә җитди йогынты ясый. 2007 дә РФ Хөкүмәте тарафыннан илдәге югары мәктәп кысаларында «Ш.т.» буенча белем бирүнең яңа юнәлешен оештыру турында карар кабул ителә. 2008 дә Россиядә беренчеләрдән булып Казан дәүләт архит-ра-төзелеш ун-тына шәһәр төзүчеләр әзерләүгә федераль лицензия бирелә, ул шул ук елда беренче абитуриентларны туплый. 2012 дә шәһәр төзүчеләрнең беренче чыга-

рылышы була һәм Казан шәһәр төзү мәктәбе формалаша башлый.

Казан Ш.т. үсешендә шәһәр тарихындагы ике күренекле вакыйга — 2005 тә шәһәрнең 1000 еллыгын бәйрәм итү һәм 2013 тә Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар Универсиадасы уздырылу мөһим этап була. Казанның 1000 еллыгына шәһәрнең үзәк өлешендә, бигрәк тә Казан Кремле, тимер юл вокзалы тирәсендә һәм яңа терр-яләрдә төзекләндерү эшләре башкарыла. Универсиада объектлары, Татарстан башкаласының транспорт инфраструктурасын шактый үзгәртеп, Ш.т.нең яңа төсмерләрен хасил итәләр. Шәһәрдәге барлык үзгәрешләр Ген. планны яңадан эшләүне көн тәртибенә куялар. 2014 тә ул эшкә Мәскәү генпланының фәнни-тикшренү һәм проектлау ин-ты керешә. 2015 тә «Татарстан 2030» икътисади үсеш стратегиясе раслана, ул Казан агломерациясен — Казан тирәли формалашкан гаять зур терр. берәмлекне төзүне күздә тота. Мәкаләгә иллюстрацияләрне к. 174–197 б.

*Әд.:* Ш п и л е в с к и й С.М. Древние города и древние булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Е ф и м о в а А.М. К вопросу о происхождении городов Волжской Булгарии. К., 1957; Исследования Великого города. М., 1976; Город Булгар. Очерки истории культуры. М., 1987; З а к и р о в а Т.Р. Архитектура советской Татарии. Проблемы становления и развития общественных зданий (на примере Казани): Дис. ... М., 1989; А й д а р о в а - В о л к о в а Г.Н. Архитектурная культура Среднего Поволжья XVI -XVII вв. К., 1997; Археологическое изучение булгарских городов. К., 1999; З о р и н А. Города и посады дореволюционного Поволжья. К., 2001; Н а д ы р о в а Х.Г. Роль ислама в развитии архитектуры Волго-Камья // Ислам в Среднем Поволжье. К., 2001; Х у з и н Ф.Ш. Булгарский город X – XIII вв. К., 2001; С а н а ч и н С. Советская Казань в архитектурной истории города // Проект Россия. 2002. № 2.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ШӘҺӘ́Р ТРА́НСПОРТЫ**, транспортның шәһәр торулыкларында (шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы посёлокларда) һәм шәһәр тирәсендә кешеләр йөртүче һәм йөкләр ташучы төрләре җыелмасы. Ш.т. — шәһәр хуҗалыгының транспорт чараларын (хәрәкәт итүче состав), юл корылмаларын һәм җиһазларын (тимер юл, автобус, көймә станцияләре, пристаньнар, рельслы юллар, тоннельләр һ.б), энергия б-н тәэмин итү чараларын (хәрәкәткә китерүче электр подстанцияләре, кабель һәм контакт челтәрләре, бензин салу станцияләре), ремонт остаханәләрен һәм з-дларын, деполар һәм гаражларны, техник хезмәт күрсәтү станцияләрен һ.бны үз эченә алган тармагы. Ш.т. пасс., йөкләр ташучы һәм махсус төрләргә бүленә. Пасс. транспортына трамвайлар, троллейбуслар, автобуслар, җиңел автомобиль транспорты, ике көпчәкле транспорт, су транспорты, метрополитен керә. 20 йөз башына кадәр шәһәрләрдә пассажирлар йөртү башлыча атлы транспорт б-н гамәлгә ашырыла. 19 йөз башыннан Казанда ул татарлар арасында таралган кәсеп була, «*барабыз*» дип атала.

1875–99 елларда атлы тимер юл («конка») файдаланыла; 1899 да Казанда үзәк Россиядәге тәүге электр трамвай линиясе ачыла. 1920 еллардан шәһәрләрдә автобуслар хәрәкәте үсеш ала. 1938 дә беренче таксилар барлыкка килә, 1948 дә Казанда троллейбус хәрәкәте башлана. Транспорт машиналары төзелешенең тиз үсеше шәһәрләрне җитәрлек дәрәҗәдә механикалаштырылган транспорт чаралары б-н тәэмин итүгә һәм алар ярдәмендә пасс. йөртүнең зур өлешен башкаруга күчүгә этәргеч бирә. 2017 ел башына, Казаннан тыш, трамвайлар — Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә, троллейбуслар — Әлмәттә, таксилар Бөгелмә, Чаллы, Чистай шәһәрләрендә файдаланыла. 2005 тән Казанда метрополитен эшли. 2017 дә респ-ка шәһәрләрендә транспорт линияләре озынлыгы: троллейбусларныкы — 130,2 *км* (ике линияле исәпләнештә), трамвай линияләре — 151,7 *км* (ике юллы исәпләнештә), метро линиясе 15,8 *км*, шәһәрләр эчендәге һәм алар тирәсендәге автобус маршрутларының озынлыгы 2,5 мең *км* дан артык тәшкил итә. Шәһәр пасс. транспорты паркында 237 троллейбус һәм 273 трамвай вагоны исәпләнә. Электр транспортына һәм автобусларга хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау деполар һәм автобус парклары тарафыннан башкарыла. Йөк ташу Ш.т. шәһәрләрдә йөкләрне гомуми максатлардагы һәм махсуслаштырылган, йөк таксомотор автотранспорты һәм сәнәгать транспорты б-н ташый. Ш.у.к. *Автомобиль транспорты, Такси, Трамвай, Троллейбус.*

*Әд.:* Б р о н е р Д.Л. Транспорт города. М., 1975; О в ч и н н и к о в Е.В., Ф и ш е л ь с о н М.С. Городской транспорт. М., 1976.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШӘҺӘ́Р УЧИ́ЛИЩЕЛӘРЕ**, тулы булмаган урта уку йортлары, 1872 елгы Шәһәр уч-щеләре уставы нигезендә *өяз училищеләре* җирлегендә оештырылалар. Халык мәгарифе министрлыгы карамагында булалар. Укытучылар өчен ставкалар санына бәйле рәвештә ике класслы, өч класслы, дүрт класслы Ш.у. була, ләкин уку срогы барысында да, башлангыч мәктәпне тәмамлаганнан соң, 6 ел тәшкил итә. Бары тик укытучылар ин-тын тәмамлаучылар укыта. Ш.у.ндә укытуның класс системасы гамәлдә була, шул нигездә Ходай кануннарыннан тыш, барлык фәннәрне дә бер укытучы укыта. Түләү зур булмый, күпчелек укучылар өчен шәһәр үзидарә органнары түли. Бер яктан, Ш.у. ярлы шәһәр балаларына белем алырга мөмкинлек бирсә, икенче яктан, тулы эчтәлекле булмаган уку йортлары була, чөнки аларда аз фәннәр укытыла: арифметика, геом., рус теле һәм әдәбият, тарих, геогр. Чит телләр һәм алгебра укытылмау сәбәпле, укуларын дәвам итәргә теләүчеләр өчен Ш.у. «тупик» уку йортына әверелә. Уч-щене тәмамлаучылар бары тик укытучылар ин-тына яисә күп булмаган техник һәм махсус уку йортларына гына керә алганнар. Казан губернасында шундыйлардан *Казан сәнәгать училищесе* генә була. Ш.у.н тәмамлаучыларның күпчелеге шәхси пр-тиеләргә хезмәткә урнаша яисә вак түрәләр булып китә.

Татарстан терр-ясендә Ш.у. Казанда (өч: 1876 да — үрнәк, укытучылар ин-ты каршында, 1880 дә — гомумшәһәр, 1905 тә — Бишбалта бистәсендә) һәм барлык өяз шәһәрләрендә: Чистайда (1878), Мамадышта, Спаста (1879), Бөгелмәдә (1880), Лаешта (1881), Зөяйдә, Буада, Алабугада, Минзәләдә (1888), Тәтештә (1902) ачыла. 1912–14 тә барлык Ш.у. *югары башлангыч училищеләр* итеп үзгәртелә.

*Әд.:* С у х о д о е в Н.С. Начальное образование в городах Казанской губернии (вторая половина XIX — начало XX вв.): Дис...К., 2002.

*Е.В.Липаков.*

**ШӘҺӘ́Р ЭНДОКРИНОЛО́ГИЯ ДИСПАНСЕРЫ́**, к. *Диспансерлар.*

**ШӘҺӘ́Р ЯНЫ́ УРМАНЧЫЛЫГЫ́**, Биектау, Лаеш, Питрәч р-ннары терр-ясендә һәм Казан эчендә урманнарны файдалану, саклау, ышыклау, яңадан утырту өлкәсендә идарә эшләрен алып бара. 1945 елда Шәһәр яны урман хуҗалыгы буларак оештырыла; 2007 дән хәзерге исемендә. Гомуми мәйданы 30213 *га*, 4 урманчылык: Биектау (8580 *га*), Иске Казан (7139 *га*), Матюшино (6837 *га*), Столбище (7657 *га*) участокларыннан тора.



Шәһәр яны урманчылыгы. Төп питомникта чыршы үсентеләре.

Урман б-н капланган мәйдан 28300 *га* тәшкил итә, ш.и. ылыслы токымнар — 11711 *га*, каты яфраклылар — 3793 *га*, йомшак яфраклылар — 12683 *га*, куаклыклар 113 *га* били. Урман барлыкка китерүче төп токымнар: нарат (39,3%), каен (21,5%), юкә (18%), биек кәүсәле имән (11,2%), усак (4,7%) һ.б. Урман типларыннан: куаклы, мүкле һәм лишайник-мүкле наратлыклар, күрәнле, сырмавыклы һәм өрәңгеле каенлыклар,төрле үләнле юкәлекләр, күрәнле усаклыклар, өрәңге-юкәле имәнлекләр өстенлек итә. Яшь урманнар — 9% тирәсе, урта яшьтәгеләр — 41%, өлгереп килүчеләре — 14%, өлгергәннәре һәм картайганнары — 36% урман мәйданын алып тора. Гомуми агач запасы — 6231 мең $м^3$, ш.и. өлгергән һәм картайган агачлар — 471,9 мең $м^3$. 2007–2017 елларда 625 *га* урман культуралары, 520 *га* ерым-сызалар һәм юл буе урман утырмалары булдырыла. Мәйданы 57,2 *га* булган урман питомнигында нарат, чыршы, карагай, ш.у. декоратив культуралар: зәңгәр чыршы, Себер эрбете, кызыл имән, матур тал, көнбатыш туясы һ.б.ның чәчкене һәм үсентесе үстерелә. Ш.я.у. җитәкчесе — И.Р.Кашафиев.

*Х.Г.Мусин.*

**ШӘҺӘ́РАРА ТЕЛЕФО́Н ЭЛЕМТӘСЕ́**, мәгълүматны электр энергиясе ярдәмендә чыбыклар аша тапшыручы һәм кабул итүче учреждениеләр җыелмасы. Рев-циягә кадәрге Россиядә Ш.т.э. Эчке эшләр министрлыгының Телеграф департаменты карамагында

була. 1882 елда С.-Петербург һәм Гатчина арасында илдәге тәүге линия (47 чакрым), шуннан соңгы елларда С.-Петербург Петергоф, С.-Петербург һәм Царское Село арасындагы линияләр корыла. 1898 дә С.-Петербург һәм Мәскәү арасындагы ерак шәһәрара телефон линиясе сафка баса. Шәһәрара телефон элемтәләре урнаштыруга ихтыяҗ артуга бәйле рәвештә, хөкүмәт хосусый эшмәкәрләргә һәм земстволарга аларны коруга рөхсәт бирә. 1902 дә Казан губерна земство идарәсе *земство телефон челтәрләрен* оештыру мәсьәләсен куя, җирле идарәләргә өяз шәһәрләрендә телефон станцияләре төзергә һәм аларны Казан б-н тоташтырырга тәкъдим итә. 1904 тә Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан Казан губернасында земство телефон челтәрен булдыруга рөхсәт бирелә. 1906 дә земство телефон станцияләре Казанда, Арча, Лаеш, Мамадыш, Чистай шәһәрләрендә, Алексеев, Мурзиха авылларында һ.б.да эшли башлый. Губерна телефон челтәрен төзү өчен һәрберсе 28 әр елга исәпләнгән 2 җирле займ чыгарыла. 1912 дә губернада гомуми озынлыгы 1700 *км* (чыбыклар — 3500 *км*) булган 33 шәһәрара телефон линиясе, 48 (Казанда 6) сөйләшү пункты эшли, сөйләшү пунктларыннан 56694 түләүле чылтырату гамәлгә ашырыла. 1907 дә телефонограммалар, 1908 дә телефонограмма-телеграммалар кабул ителә башлый. Беренче бөтендөнья, Гражданнар сугышы елларында телефон элемтәсе челтәренә зур зыян китерелә, чит ил фирмалары һәм аларның Россиядәге национализацияләнгән филиаллары тарафыннан матди-техник тәэмин итү бозыла. 240 *км* лык линияләр, 8 мең *км* озынлыкта чыбыклар, һавадан сузылган 42 *км* кабель төзекләндерелергә тиеш була. Кама аша Мурзиха авылы тирәсендә сузылган кабель яраксыз хәлгә килә һәм аны алмаштыру таләп ителә. Телефон элемтәсенең финанс хәлен яхшырту максатында РСФСР ХКСның 1922 ел 2 июнь Декреты б-н телефон челтәрләре хуҗалык исәбенә күчерелә. 1926 да Казан һәм Мәскәү арасында турыдан-туры телефон элемтәсе урнаштырыла. 1933 тә Казан ике яклы төркемле телефон элемтәсенә кертелә. 1934 нең 1 октябрендә *Казан шәһәр телефон челтәренең* шәһәрара элемтә цехы мөстәкыйль пр-тиегә әверелә һәм «Казан республика шәһәрара телефон станциясе» дип атала. Эшләүчеләр саны 66 кеше тәшкил итә. Шәһәрара элемтә өчен элеккеге земство телефон станциясе коммутаторы, ш.у. ачкычсыз система итеп җиһазландырылган иске шәһәр телефон станциясе элементлары файдаланыла. Казанда һәрберсенең 12 шнурлы парлары, сөйләшү ачкычлары һәм 20 чакыру клапаннары булган 3 коммутатор гамәлгә кертелә. Станция 17 чылбырга, 18 турыдан-туры абонентка хезмәт күрсәтә. Чылбырларга чамадан тыш күп эш йөкләнә, аларның кайберләре 5–10 районга хезмәт күрсәтәләр. Шәһәрара сөйләшүләр 4 будкадан башкарыла. 1930 елларда илнең эре үзәкләре б-н элемтәләр урнаштырган яңа линияләр булдырыла, шәһәрара телефон челтәреннән керемнәр арта, телефон чыбыкларын файдалану коэффициенты күтәрелә. 1939 да Казан шәһәрара телефон станциясендә (МТС) югары төгәллекле тыгызлагыч аппаратура файдалануга тапшырыла, ул Казан–Мәскәү, Казан–Свердловск линияләренә урнаштырыла, Казан СССРның Ш.т.э. челтәренә кушыла. 1940 та Казан шәһәрара телефон станциясе СССРның иң эре 25 станциясе исәбенә керә. Бөек Ватан сугышы елларында, шәһәрара элемтә пункты буларак, Казанның әһәмияте арта. СССР Элемтә халык комис-ты тарафыннан Мәскәү–Казан элемтә линиясенең үткәрүчәнлек сәләтен үстерү буенча чаралар күрелә. Линия корылмалары, көчәйтү пунктлары булдырыла, җиһазлар көйләнә. Яңа чаралар Казан һәм Мәскәү, Сталинград, илнең башка торак пунктлары арасында ышанычлы телефон элемтәсен тәэмин итәләр. 1950 елларда Ш.т.э. алга таба үсеш ала. Илдәге яңа системалар турыдан-туры телефон элемтәсе, ш.у. телеграф һәм фототелеграф сигналларын тапшыру өчен кулланылучы стандарт телефон каналлары бәйләме булган шәһәрара линияләр төзү мөмкинлеге бирә. 2–3 телефон каналын берләштерү юлы б-н радиотапшырулар программаларын югары сыйфатлы тапшыру өчен шәһәрара каналлар булдырыла. 1959–62 дә респ-каның Казан б-н тәүлек әйләнә шәһәрара элемтәсе булган районнарының саны 11 дән 37 гә кадәр арта. Респ-када телефон каналларының озынлыгы өзлексез үсә бара. Татарстанның нефть районнары б-н элемтәгә аерым игътибар бирелә. 1960 елларда күп каналлы линияләрне гамәлгә кертү башлана, шәһәрара станцияләрнең сыйдырышлылыгын арттыру һәм аларны автоматлаштыру буенча чаралар күрелә. 1968 дә Казан илдә шәһәрара элемтә өчен АМТС-1 тибындагы 20 каналлы автомат телефон станциясе корылган һәм файдалануга тапшырылган 3 нче шәһәр була, һәм Мәскәү, Свердловск, Пермь, Уфа, Ижевск, Чабаксар, респ-каның Бөгелмә, Түбән Кама, Әлмәт, Лениногорск шәһәрләре б-н автомат телефон элемтәсе булдыра. 1966–70 тә респ-каның шәһәрара телефон челтәрендә телефон каналларының саны 2 тапкыр арта. 1973 тә көн саен уртача алганда 34 мең шәһәрара сөйләшү эшкәртелә. 1971–74 тә респ-када шәһәрара элемтә каналларының озынлыгы икеләтә арта, автомат һәм ярымавтомат шәһәрара каналларының өлеше 49% тан 70% ка кадәр үсә. 1970 тә Казанда 1200 каналлы АМТС-3 аппаратуралы яңа шәһәрара телефон станциясе бинасы төзелә башлый, 1977 дә ул файдалануга тапшырыла. Бу көнгә 55 меңгә кадәр сөйләшүләр башкару һәм заманча телефон элемтәсенә респ-каның барлык шәһәрләрен һәм район үзәкләрен диярлек тоташтыру мөмкинлеге бирә. 1995 тә АМТС-3 координатлы шәһәрара станциясе 15390 тоташтыру ноктасы булган «Alcatel 1000 S-12» электрон станциясе б-н алыштырыла. Бераздан шундый ук станция Чаллы шәһәрендә урнаштырыла. Соңрак металл элемтә кабельләренә алмашка җепселле оптик кабельләр килә. 2005 тә шәһәрара зона элемтә линияләренең озынлыгы 4313,9 *км*, ш.и. җепселле-оптик линияләр 2680,3 *км* тәшкил итә. 68 мең зона цифрлы телефон каналы булдырыла, 5 синхрон бөҗрәдән торган югары тизлекле сыгылмалы телекоммуникацион элемтә челтәре төзелә. Респ-ка шәһәрара элемтә челтәрендә илдә һәм чит илләрдә эшләнгән STM-16, STM-4 һәм STM-1 дәрәҗәсендәге синхрон цифрлы иерархия җиһазлары, ш.у. DWDM, Gigabit Ethernet һәм Fast Ethernet технологияле җиһазлар гамәлгә кертелә.ТРның зона элемтәсе шәһәрара челтәрләре файдаланучыларны заманча хезмәт күрсәтүләр — элемтәнең коммутатор һәм бүленгән каналлары буенча телефон элемтәсе, мәгълүмат тапшыруның югары тизлекле челтәре, телематик хезмәтләр, киң полосалы мөмкинлек, аудио- һәм видеоконференцияләр хезмәтләре, интернет хезмәте күрсәтүләр б-н тәэмин итү мөмкинлеге бирәләр. Респ-каның шәһәрара зона элемтәсен үстерү — яңа NGN буыны челтәрләренә күчү буенча эшләр төгәлләнде.

1997 дә Казан МТСы һәм Казан телеграфы Казан шәһәрара телефон-телеграф станциясенә берләштерелә. ТРда гомуми файдаланудагы шәһәрара һәм халыкара телефон элемтәсе хезмәтләре ерак элемтә операторлары «Ростелеком», «МТТ», «Вымпелком», «Компания ТТК», «МТС» акц. җәмгыятьләре, «Эквант», «Наша сеть» ҖЧҖләре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Эшләүчеләр саны — 5000 меңнән артык кеше (2017).

*Әд.:* Орлова А.Ф. Время и связь. К., 1988; Людей связующая нить. К.,2003.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШӘҺӘРЛЕ́К** (археол.), борынгы ныгытылган торулык калдыклары. Гадәттә, агач яки таш диварлардан, туфрак урлардан һәм чокырлардан торган бер яки берничә саклану линияләре б-н ныгытылган. Башлыча елга үзәннәре янындагы табигый калкулыкларда, борыннарда, текә ярлы үрләрдә урнашкан. Урта Идел буенда беренче Ш.ләр бронза гасырның соңгы чорында барлыкка килә.



Болгар шәһәрлеге ныгытмалары реконструкциясе.

Аеруча әлгерәге тимер гасырда һәм урта гасырларда таралыш алалар. Әлеге торулыклар арасында сугыш куркынычы очрагында тирә-яктагы халык кереп яшеренгән сыену Ш.ләре һәм даими яшәү урыны булган Ш.лар аерылып тора. Алар биләгән мәйданнар төрле зурлыкта — берничә дистә $м^2$ дан берничә дистә мең $м^2$ га кадәр. Татарстан терр-ясендә 200 ләп Ш. булуы мәгълүм. Аларның күпчелек өлеше Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорларына карый: Арча, Биләр, Богдашкино, Болгар, Алабуга, Гремячий Ключ, Имәнкискә, Камай, Кашан, Суар Ш.ләре һ.б.

*А.М.Гобәйдуллин.*

**«ШӘҺРИ́ КАЗА́Н»**, атналык иҗтимагый-сәяси шәһәр газетасы. Хәзерге оештыручысы — «Татмедиа» АҖ. 1990 елның 17 августыннан Казанда татар телендә нәшер ителә. Төрле елларда баш мөхәррирләре — Х.Г.Гайнуллин, И.Г.Илдарханов, М.М.Әгъләтдинов, М.Г.Мортазин, Г.И.Сабирова,


Шәһри
КАЗАН
һәйкәлләр ЯҢАДАН «ТУАЧАК»...

«Шәһри Казан» газетасы.

Р.Р.Сабиров (2019 дан). Шәһәр һәм респ-каның законнар чыгару һәм башкарма хакимият эшчәнлеге, Казанның, Татарстан, Россиянең социаль-сәяси, мәдәни, рухи тормышы турында мәгълүмат бирә, Россиядәге, якын һәм чит илләрдәге татар диаспорасы б-н бәйле вакыйгаларны яктырта.

**ШӘЯХМӘ́ТОВ** Камил Мәхмүд улы (15.10.1928, Казакъстан ССР, Күкчәтау ш. — 4.5.1995, Алма-Ата ш.), нәкышьче, Казакъстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1965). Н.В.Гоголь исем. Алма-Ата сынлы сәнгать уч-щесен (1948), И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын, Ю.Непринцев остаханәсен (1956) тәмамлый.





К.М.Ш ә я х м ә т о в. 1. «Сарык көтүе». 1961; 2. «Кыр станында». 1982.

1956 елдан Алма-Атада яши; Рәссамнар берлеге әгъзасы (1957). Ш. — күренекле совет нәкышь остасы, Казакъстанның заманча сәнгатенә нигез салучыларның берсе. Көнкүреш, тарихи, портрет һәм пейзаж жанрларында сюжетлы-тематик картиналар иҗат итә. 1950 еллар соцреализм стилендә эчтәлеге һәм композициясе б-н масштаблы картиналарында халык тормышының эпик панорамасын, казакъ даласында барган яңалык-үзгәрешләрне чагылдыра. Аның картиналары образларның монументаль күтәренкелеге, чынбарлыкны оптимистик кабул итү, натурага якынлык, колачлылык, якты төсләр гаммасы б-н аерылып тора. Төп әсәрләре: «Җиңүчеләр» (диплом эше), «Фермада» (икесе дә — 1956), «Туган авылда», «Дачада» (икесе дә — 1957), «Авылдан хат» (1958), «Тынычлык турында җыр», «Яшьләр бригадасы», «Алтай күренеше» (барысы да — 1960), «Яңа пешкән икмәк», «Сарык көтүе» (икесе дә — 1961), «Чабаннар бәйрәменә» (1962), «Дала күренеше» (1965), «Игенчеләр» (1976), «Даладагы ак шәһәр» (1978), «Совхоз парткомында» (1980), «Кошчида ярлылар комитеты» (1981), «Кыр станында» (1982) һ.б. Ш. пейзажларында табигатьнең лирик образлары сурәтләнә: «Җәйләүдә» (1955), «Өйлә» (1961), «Яңа иртә» (1965), «Яңа яуган кар» (1966), «Салынкы көн» (1967) һ.б. «Балыкчы Саулә» (1962), «Казакъ ССРның халык рәссамы А.Г.Галимбаева» (1977) һ.б. портретлар авторы.

1949 дан бөтенсоюз — «Бөек Октябрьнең 40 еллыгына» (1957), «ВЛКСМның 40 еллыгы» (1958), «Совет властена 40 ел» (1967), «В.И.Ленинның тууына — 100 ел» (1970), «СССР — Ватаныбыз» (1972), «Без коммунизм төзибез» (1981), «Советлар иле» (1987) (барысы да — Мәскәү) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Алма-Атада (1967, Е.Сидоркин белән бергә), Казанда (1982) уздырыла. Әсәрләре Третьяков галереясында (Мәскәү), А.Кастеев исем. Казакъстан Респкасы Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Астана шәһәрендәге Заманча сәнгать музеенда саклана. «Почёт билгесе» ордены, медаль белән бүләкләнә.

*Әд.:* В а н д р о в с к а я Е. К. Шаяхметов: Буклет. А.-А., 1957; Изобразительное искусство Казахской ССР. М., 1974; У с а ч ё в а Л.П. Камиль Шаяхметов. Живопись: Альбом. М., 1986.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ШВАРЦ** Соломон Моисеевич (1.5.1892, Вильно губ., Вильно өязе Таборишки местечкосы — 1.8.1937, Казан), гигиенист, мед. фән. д-ры (1935). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1922), шунда ук госпиталь терапиясе клиникасында эшли, 1926–29 елларда социаль гигиена кафедрасы каршында штаттан тыш прозектор, 1930 да мед. ф-ты гыйльми секретаре. Бер үк вакытта, 1922–24 тә, ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-тының санитария бүлеге мөдире ярдәмчесе һәм сан.-профилактика бүлеге мөдире. ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-тының Социаль гигиена ин-тында хезмәт гигиенасы бүлеген оештыручыларның берсе (1926). 1931–32 дә Германия һәм Швейцариядә фәнни командировкада була. Хезмәтләре а.х. хезмәтчәннәренең хезмәтен саклауны оештыру мәсьәләләренә карый. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Устав больничной кассы. СПб., 1913 (автордаш); К вопросу об изменении количества комплемента крови при отравлении хлором, хлороформом, эфиром и бензином // Профессиональная патология и гигиена. 1928. № 3; Санитарная статистика и диалектика // Казан. мед. журн. 1930. № 2; К методике изучения роли метеорологического фактора в возникновении простудных заболеваний // Гигиена труда и техника безопасности. 1936. № 1.

*Әд.:* Казанские профессора-гигиенисты: Биогр. словарь. К., 1995.

**«ШВЕЙЦА́РИЯ»**, к. *Терлек таулары.*

**ШВЕЦО́В** Владимир Александрович (3.7.1955, Новгород ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. д-ры (2004). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1977). 1977–83 елларда «Камдорстрой» (Чаллы ш.) трестында мастер, прораб. 1983–87 дә 930 нчы төзелеш идарәсендә баш инженер, 1987–93 тә 928 төзелеш идарәсе башлыгы. 1994–95 тә «Камдорстрой» АҖ ген. директоры. 1995–2007 дә ТР Премьер-министры урынбасары. Бер үк вакытта, 1995–96 да, ТРның Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү дәүләт ком-ты рәисе, 2001–07 дә ТР транспорт һәм юл хуҗалыгы министры. 2008–11 дә Россия Федераль юл агентлыгының Ерак Көнчыгыш регионында Юл төзелеше буенча регионара дирекция директоры (Хабаровск ш.). 2011 дән Мәскәү төзелеш департаменты башлыгы урынбасары. Хезмәтләре төбәк-тармак комплексы б-н идарә итүне оештыру методологиясенә карый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШВЫ́ДКИН** Эдуард Кузьмич (25.8.1941, Смоленск өлкәсенең Красный р-ны Пахомово а. — 30.8.2009, Казан), геолог-геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (1997), проф. (2009), РФнең мактаулы җир асты байлыклары разведчигы (2001). Казан ун-тын тәмамлый (1965), Себер, Удмуртия һәм Татарстанның фәнни һәм җитештерү берләшмәләрендә, Алжирда (1973–76, 1979–81) эшли, Казан ун-тында укыта (1968–81, 2007–09). Хезмәтләре геофизика, геохимия, гидрогеол., экология, битумнар табуга карый. Ш. геофизик алымнар б-н фильтрлану потенциалларын бәяләү; битум һәм үзле нефть чыганакларын эшкәрткәндә углеводородларга җылылык тәэсирен җир өстендәге магнитлы съёмка ярдәмендә контрольдә тоту; геофизик һәм геохимик комплекслар кулланып геол. структураларның нефтьлелеген бәяләү методикаларын эшли.

Х е з м.: Геофизические методы подготовки и контроля процессов эксплуатации месторождений природных битумов. М., 2000 (автордаш); Геофизические и геохимические технологии прогноза и оценки нефтеносности перспективных объектов. К., 2008 (автордаш).

**ШЕББУ́Й**, и ш б ә л ә ч ә ч ә к (Matthiola), әверчә чәчәкләр семьялыгыннан бер-, икеһәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 55 төре билгеле, Евразия, Африка, Австралиядә таралганнар. ТР терр-ясендә

бер төре — хуш исле Ш. (M. fragrans) бар. Идел алдында очрый. Ташлы тау битләрендә, карбонатлы ачылмаларда таралган. 30–35 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыры үзәк. Сабагы аз гына ботаклы, аскы ягы куе яфраклы, яфраксыз чук б-н тәмамлана. Яфраклары чиратлашкан, ланцетсыман, бөтен яки уемтыклы-каурыйсыман-теленмә, кырыйлары дулкынсыман. Чәчәкләре хуш исле, саргылт-көрән, чукка җыйналган, күбесенчә кич б-н ачыла. Җимеше — кузакчык. Май–июньдә чәчәк ата. Июнь–июльдә җимеш бирә. Орлыктан үрчи.Тәүлекнең караңгы вакытында күбәләкләр б-н серкәләнә. Декоратив үсемлек буларак үстерелә. Баллы үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ШЕБУ́ЕВ** Георгий Николаевич (17.4.1850, Түбән Новгород губ. Княгинино өязе — 16.6.1900, Казан губ. Казан өязе), механика өлкәсе галиме. Түбән Новгород дворяннар ин-тын (1868) һәм Казан ун-тын (1873) тәмамлый. 1876–78 елларда Мәскәү техник уч-щесендә укыта. 1878–93 тә Казан реаль уч-щесендә, бер үк вакытта, 1879–93 тә, Казан ун-ты приват-доценты. 1893 тән Константин межалау ин-ты (Мәскәү) сыйныфлары инспекторы. Хезмәтләре теоретик механикага һәм физикага, кватернионнар теориясен охшаш рәвештә һәм бердәй үзгәрешле системалар механикасына яраштыруга багышлана. Казан ун-ты каршындагы Табигыятьчеләр җәмгыятенең физика-матем. секциясе әгъзасы-гамәлгә куючысы; Казан физика-матем. җәмгыятен оештыручыларның берсе.

Х е з м.: Руководство к теоретической оптике: В 2 вып. К., 1886–87; Курс механики системы материальных точек. К., 1890; К вопросу о распределении температуры внутри текущей несжимаемой жидкости и омываемых ею тел. К., 1893.

**ШЕВЕЛЁВ** Анатолий Иванович (27.7.1936, Тубыл ш.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1997), ТРның атказ. геологы (1995), РФнең мактаулы җир асты байлыклары разведчигы (1996). Томск политехник ин-тын тәмамлый (1959), Көнбатыш Себернең җитештерү оешмаларында эшли. 1970 елдан ЦНИИгеолнерудта, баш фәнни хезмәткәр (2004 тән) (1979–83 тә Алжирда). Бер үк вакытта, 1997 дән, Казан ун-ты профессоры. Татарстан файдалы казылмалар запасы буенча респ-ка комиссиясе рәисе (1992–97). Хезмәтләре руда һәм руда булмаган файдалы казылмалар чыганакларына, металлогениягә карый. Ш. СССР терр-ясендә магнезия чималы чыганакларының төп урнашу законччалыкларын билгели, магнезит чыганаклары ачыкланган 3 төбәк һәм мәйданны билгели; Алжирда металл булмаган токымнарның минерал-чимал базасының перспектив үсеш программасын эшли. Татарстан терр-ясендә файдалы казылмаларны һәм җир асты су чыганакларын планлаштыру, фаразлау, эзләү, бәяләү эшләренә җитәкчелек итә.

Х е з м.: Генетические типы, закономерности размещения и прогноз месторождений брусита и магнезита. М., 1984 (автордаш); Минерально-сырьевая база магнезита и брусита России. К., 2003 (автордаш).

**ШЕ́ВИЦ Л. БАСМАХАНӘСЕ́**, Казанда. Шәһәрдәге беренче хосусый басмаханә (басмаханә, ташбасма һәм хәреф кою ширкәте). 1841 елда гравёр Л.Шевиц тарафыннан ачыла, яхшы җиһазланган, заказ бирүчеләрне, бигрәк тә татар наширләрен үз вакытында һәм эшне сыйфатлы итеп башкаруы б-н җәлеп итә. Басмаханә ачылган елда 11 татар китабы басыла. Хосусый басмаханәләрдә татар китапларын бастыруны тыю турындагы 1845 елгы указга кадәр китапларның гомуми саны 35 данә тәшкил итә. 1849 да Шевиц басмаханәне Н.П.Коковинга сата, тагын 10 татар китабын бастырып чыгарырга өлгерә. Басмалар арасында Коръән, Һәфтияк, татар әлифбалары, мәдрәсәләр өчен уку китаплары, «Кыйссаи Йосыф», «Гыйбрәтнамә» поэмалары дөнья күрә.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. У истоков татарской книги. К., 1992; Г а б д е л ь г а н е е в а Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005.

*Г.Г.Габделганиева.*

**ШЕВЧЕ́НКО** Олег Андреевич (16.9.1944, БАССРның Яңавыл ш. — 5.6.2007, Яшел Үзән р-ны Васильево штп), техник-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). Казан авиация техникумын тәмамлый (1971). 1963–2005 елларда Казан моторлар төзү ҖБдә эшли: ВЛКСМ ком-ты секретаре урынбасары, өлкән диспетчер, смена башлыгы, мастер, башлык урынбасары, цех башлыгы, ген. директор урынбасары (1989 дан), баш инженер урынбасары (2001 дән). Дәүләт бүләге туфракны чәчү алдыннан эшкәртү өчен блоклы-модульле культиваторлар җитештерүне булдыруда, технол. нигезләүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШЕВЧЕ́НКО** Тарас Григорьевич (9.3.1814, Киев губ., Звенигород өязе Моринцы а. — 10.3.1861, С.-Петербург), украин шагыйре, рәссам. «Кобзарь» шигырь җыентыгы (СПб., 1840), «Катерина» (1839; СПб.та нәшер ителә, 1840), «Гайдамаклар» («Гайдамаки», СПб., 1841), «Наймичка» (1845; «Записки о Южной Руси» ж-лында нәшер ителә, 1857, 2 т.), «Мария» (1859; СПб.та нәшер ителә, 1907) поэмалары һ.б. авторы. 1857 елның 13 сентябрендә сөргеннән кайтып барганда, Ш. Казанны күзәтә һәм көндәлегенә: «Казан шәһәрчеге — Мәскәүнең бер почмагы. Бу әйтемне мин беренче тапкыр 1847 дә, фельдъегерь б-н Оренбургка озатылганда, Сембер губернасының почта станциясендә ишеттем. Сембернең ниндидер таза гына бер дала кешесе, мине озатып баручыга Казанның матурлыгын тасвирлаганда, сөйләгәннәрен шушы шома әйтем б-н төгәлләп куйды. Бүген иртүк Казанны ерактан күрдем, һәм күптән ишетелгән мәкаль үзеннән-үзе искә төште һәм ирексездән телдән ычкынды. Пароход якорьне төшерүгә, мин ярга сикереп төштем дә, чирек сумга татар арбасына утырып шәһәргә киттем. Ерактан да, якыннан да, әченнән дә Казан бик тә Мәскәүнең бер почмагын хәтерләтә: чиркәүләрдән, чаң манараларыннан алып, күмәчләргә кадәр, бөтен җирдә, адым саен ак ташлы Мәскәүнең тәэсире сизелә. Хәтта, һичшиксез, татарлар заманы истәлеге булган



Т.Г. Шевченко.

Сөембикә манарасы Сухарев манарасының карындаш кыз туганын хәтерләтә. Кремльгә илтүче Зур урам (әлбәттә, Мәскәү урамы) үзенең һавалылыгы һәм түшәлгән юлы б-н Нева проспектына охшаган. Урам, өч зур ионик портик б-н бизәлгән университетның гаҗәеп бинасы б-н башланып китә. Кызганыч, бу матур бинага мәйдан җитешми. Пароходка кайтып барышлый, юлның уң ягында Явыз Иван патша Казанны яулаганда һәлак булганнарның сөякләре өстендә корылган һәйкәл күрдем. Әлеге портиклы кисек пирамида Явыз Иван патша чатыры торган урында куелган бугай. Сагышлы һәйкәл», — дип язып куя.

Ә с ә р.: Сочинения: В 4 т. М., 1977.

*Әд.:* Знаменитые люди о Казанском крае. К., 1990.

**ШЕВЫ́РЕВА** Руфия Мөбарәк кызы, (11.8.1947, Казан), психиатр, медицина д-ры (1992), җәмәгать эшлеклесе. Рига мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Латвия ССР, Юрмала шәһәренең «Булдури» (1971 дән), «Яункемери» (1979 дан) санаторийларында эшли. 1980–91 елларда Курортология фәнни-тикшерү ин-тында, 1991 дән Латвия Респ-касы Эчке эшләр министрлыгы поликлиникасында (Рига). Хезмәтләре курортология, йөрәк ишемиясе б-н авыручыларны дәвалаганда эмоциональ-стресс психотерапиясе куллануга карый. Мәхәллә советы рәисе, мәхәлләнең «Нур» мәгълүмат бюллетене мөхәррире (Рига), Россия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте Президиумы әгъзасы.

**ШЕГУ́РОВ** Юрий Валентинович (21.6.1952, Югары Ослан р-ны Зөя а.), спортчы, тренер (стендта ату), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1976), РСФСР, Россиянең атказ. тренеры (1986, 1990). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1974). «Уңыш» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Тәтеш ш.). «Мәскәүнең зур призы» халыкара ярышларында җиңүче (1976), СССР чемпионатында көмеш медаль ала (1974). 1974 елдан Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (Тәтеш), 1980 нән машина төзелеше з-дының (Ижевск ш.) «Металлист» СКда (бер үк вакытта ату үзәге башлыгы) тренер. Шәкертләре арасында — халыкара класслы спорт осталары, СССР, Европа, дөнья чемпионатларында җиңүчеләр, СССР, Европа, дөнья кубоклары ияләре: В.Крылов, И.Кузнецов, И.Нуруллин, Е.Пушина, А.Родионов.

**ШЕ́ЙБУТ** Юрий Евгеньевич (5.6.1949, Тбилиси — 12.5.1994, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1991). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), Казан югары уку йортларында эшли. 1984 тән Россия Мәгариф академиясенең Махсус урта белем фәнни-тикшеренү ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1991 дән). Хезмәтләре молекуляр кристалларның когерент спектроскопиясенә, мах-

сус урта белем системасында физика б-н математиканы укыту методикасына карый. Ш. молекуляр кристалларда (мохитнең башлангыч тигезләнешсезлеген исәпкә алган хәлдә) үзиндукцияләнгән үтәкүренмәлекнең (СИП) ярым классик теориясен төзи. Молекуляр кристаллар спектрының экситон өлкәсендә экситон СИП һәм нутация эффектларын алдан әйтә. Экспериментны теоретик җәһәттән тасвирлый, системада корреляция ясауның характерлы вакытларын, үтә нурланыш импульсының тоткарлану вакытын һ.б. параметрларны билгели.

Х е з м.: Эффекты резонансного нелинейного когерентного взаимодействия лазерного излучения с молекулярными кристаллами и их применение // Укр. физ. журн. 1981. Т. 26, № 5 (автордаш); Исследование релаксационных процессов в кристалле дефинила с пиреном методом оптического сверхизлучения Дикке // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1985. Т. 89, вып. 4–10 (автордаш); Оптическое сверхизлучение в кристаллах как метод исследования релаксационных процессов // Изв. АН СССР. Сер. физ. 1989. Т. 53, № 12.

**ШЕЙНКМА́Н** Яков Семёнович (22.12.1890, Тубыл губ. Петропавловский Завод пос. — 8.8.1918, Казан), партия эшлеклесе. РСДРП(б) әгъзасы (1910). 1910 елда Петербург ун-тында укый, студентлар чуалышларында катнашканы өчен кулга алына. Иреккә чыгарылганнан соң, Швейцариягә эмиграциягә китә (1912), 2 нче Интернационал эшендә катнаша. 1914 тән Екатеринбург шәһәрендә партия эшен алып бара. 1917 дә большевикларның «Уральский рабочий» г-тасы өчен басмаханә оештыруда, үзе үк лекцияләр укыган партия мәктәбе булдыруда катнаша; Екатеринбург шәһәр думасына гласный итеп сайлана. 1917 нең августыннан Казанда, губерна азык-төлек ком-ты рәисе урынбасары; Эшче, солдат, крәстиян депутатлары советының РСДРП(б) фракциясе рәисе. Петроградта 1917 елгы Окт. рев-циясендә катнаша, Хәрби-революцион ком-тның Тикшерү комиссиясе әгъзасы. 1917 нең ноябреннән Казан губерна башкарма ком-ты рәисе, бер үк вакытта, 1918 нең февраленнән, Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касы ХКС рәисе, марттан — РКП(б)ның губерна ком-ты рәисе. Революцион штаб әгъзасы, татар милли-демократик хәрәкәтен бастыруны җитәкләүчеләрнең берсе. Советларның 5 нче Бөтенроссия съезды делегаты (1918 нең 4 июле, Мәскәү), РСФСР Конституциясен эшләү комиссиясе әгъзасы. 1918 дә Мәскәүдә сул эсерлар фетнәсен бастыруда катнаша, фетнә эше буенча РСФСР ХКС Тикшерү комиссиясе әгъзасы. 19 июльдән Казанны КОМУЧ Халык армиясеннән һәм Чех-словак корпусыннан саклауны җитәкли; шәһәр алынганнан соң кулга алынып, атып үтерелә.

*Әд.:* Ш е й н к м а н С.А. Яков Семёнович Шейнкман // Пути революции. 1922. № 1; М у х а р я м о в М. Я.С.Шейнкман (1890–1918) // Борцы за счастье народное. К., 1967; Октябрь в страницах биографий. Свердловск, 1987.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ШЕЙХЦЕ́РИЯ** (Scheuchzeria), шейхцериячәләр семьялыгыннан бердәнбер үсемлекләр ыругы. 1–2 төре билгеле, Төньяк ярымшарның салкын һәм уртача өлкәләрендә таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре бар — саз Ш.се (S. palustris) Идел алдында очрый. Зур елгаларның борынгы аллювиаль террасаларына туры килүче торфлы сазлыкларда һәм йөзмә «үлән-утраулар»да үсә. 10–25 *см* биеклектәге күпьеллык үләнчел үсемлек. Тамырчасы шуышма, төерле, яфрак җиңсәләре калдыклары б-н капланган. Сабагы туры. Яфраклары чиратлашкан, тар кыяк, аскы өлешендә ярымцилиндрсыман. Чәчәкләре вак, күрексез, яшькелт-сары, кабарынкы чук чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — коры күптабакча. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Һава куышлыгы булганлыктан орлыклары яхшы йөзә һәм су б-н тарала. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Торф ясаучы үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ШЕКӘ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 37 *км* төньяктарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 451 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Шики, Урмяк исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1205,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 10 ир-ат; 1859 да — 379, 1897 дә — 550, 1908 дә — 638, 1920 дә — 661, 1926 да — 598, 1938 дә — 662, 1949 да — 544, 1958 дә — 483, 1970 тә — 528, 1979 да — 512, 1989 да — 429, 2002 дә — 429 кеше.

**ШЕКУ́Н** Лев Яковлевич (1.1.1931, Омск ш. — 29.6. 1967, Казан), физик, физика-матем. фән. канд. (1956). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, (1953) шунда ук эшли. Хезмәтләре ЭПР спектрлары теориясенә, кристаллардагы ионнарның оптик спектрларына һәм бу спектрларга тышкы тәэсир йогынтысына карый. Ш.ның кристаллик кыр теориясе һәм үз эчендә лантаноид катнашмалар булган кристаллардагы спин-рәшәткәле релаксация турындагы хезмәтләре радиоспектроскопиянең бу өлкәсендә башлангыч адымнар була. С.А.Альтшулер тәкъдиме б-н Ш. Казан ун-тында парамагнит резонансын һәм кристаллардагы релаксацияне тикшерү өчен тәҗрибә базасы булдыра.

Х е з м.: Резонансное парамагнитное поглощение ультразвука в некоторых солях редкоземельных элементов // Изв. АН СССР. Сер. физ. 1957. Т. 21, № 6 (автордаш); Параметры кристаллического поля тетрагональных центров в кристаллах со структурой шеелита // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1965. Т. 2, № 9; Спин-решёточная релаксация неодима в монокристаллах некоторых шеелитов // Физика твёрдого тела. 1967. Т. 9, № 3 (автордаш).

**ШЕКШЕ́** (Иске Шекше) авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 11 *км* төньяктарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 293 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында По речке Шикше, Старая Шикша исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.дә волость идарәсе урнаша; мәчет, мәктәп, 2 тимерче алачыгы, 1 казна шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1350,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 174 ир-ат; 1859 да — 418, 1897 дә — 658, 1908 дә — 757, 1920 дә — 740, 1926 да — 728, 1938 дә — 563, 1949 да — 558, 1970 тә — 387, 1979 да — 372, 1989 да — 307, 2002 дә — 327 кеше.

**ШЕ́ЛИН** Геннадий Густавович (16.1.1937, Казан), җылылык өлкәсе технигы, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003), ТРның атказ. энергетигы (2002). Казан энергетика техникумын тәмамлый (1966). Хезмәт эшчәнлеген 1956 елда Сталинград шәһәрендә ТЭЦ төзелешендә монтажчы слесарь буларак башлый. 1957–77 дә Казан 2 нче ТЭЦта пар турбиналары машинисты, турбиналар цехы башлыгы урынбасары, житештерү бүлеге инженеры. 1977–2002 дә «Татэнерго» АҖдә: җылылык техника хезмәте башлыгы, җылылык-механика җиһазларыннан файдалану хезмәте башлыгы (1983 тән), яңартып техник җиһазландыру, реконструкцияләү һәм энергия саклау хезмәте башлыгы (1990 нан). Дәүләт бүләге югары басымлы казаннар өчен термик ысул б-н су әзерләүнең югары нәтиҗәле һәм экологик камилләшкән технологиясен эшләү һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШЕЛКО́ВНИКОВ** Яков Михайлович (1774–1809, Казан), архитектор. Рус классицизмы вәкиле. 1785 елда Петербург САнә укырга керә, бер үк вакытта анда 1797 гә кадәр эшли һәм 1 нче дәрәҗә аттестат ала. 1797–1804 тә С.-Петербургта арх. А.Д.Зайцевның ярдәмчесе була. 1804 тән Казан губер-



Я.М. Ш е л к о в н и к о в. Шәһәр хастаханәсе. Черек күлдән күренеше. В.Турин литографиясе.1834.

на архитекторы. Ш. проекты буенча Казанда шәһәр хастаханәсе (1806), төрмә кальгасы (1807), Никола Тульский чиркәве (1810–16), *Казан Богородица хатын-кызлар монастыреның* Настоятель (1810–32) һәм Никольский (1832–43) корпуслары төзелә.

*Әд.:* Муртазина Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

**ШЕМЕ́ЛКА** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Мишә елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 16,6 *км*. Бассейнының мәйданы 56,8 *км*². Питрәч р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Яңа Шигали авылының көньяк чигендә, тамагы Колай авылының көньяк-көнбатыш чигендә. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 60 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Ш.ның 0,8 дән 4,3 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,41 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы143 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 130 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 *м*³/*с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 1,7 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШЕҢШЕҢӘ́Р** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 24 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Киров өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 511 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1602–03 тән Кучюковская исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кучукова Пустошь буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез аяк киеме тегү, сәүдә б-н шөгыльләнә, Казаннан Малмыжга, Алабугага һәм ары таба көнчыгышка юнәлгән Себер трактыннан үтүчеләргә хезмәт күрсәтә. 20 йөз башында 3 җамигъ мәчет (1849, 1854, 1911), 3 мәдрәсә, киез итек цехы, берничә сәүдә һәм юлаучылар йорты эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 2551,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Носла волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән -Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 150 ир-ат; 1859 да — 976, 1884 тә — 1394, 1905 тә — 1510, 1926 да — 1725, 1938 дә — 1355, 1949 да — 756, 1958 дә — 592, 1970 тә — 640, 1979 да — 528, 1989 да — 519, 2002 дә — 501 кеше.

**ШЕПКӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Зәй елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 15 *км*. Бассейнының мәйданы 72,7 *км*². Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Шепкә авылыннан 5 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Иске Пәлчекәү б-н Бүресарай авыллары арасында. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 58 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. Ш.нең 1,1 дән 8 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар, иң зурысы — Аксар елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 72 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 63 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,022 *м*³/*с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан артыграк. Ш. бассейнында суының гомуми күләме 0,04 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШЕПКӘ́Н** (Camelina), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 төре билгеле, Евразия, Төньяк Африка һәм Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Вак орлыклы Ш. (C. microcarpa) барлык районнарда да очрый, далаланган тау битләрендә һәм болыннарда, кырларда, юл буйларында, язгы чәчүлекләрдә, төкле Ш. (C. pilosa) Куйбышев сусаклагычы утрауларында һәм көзге культуралар арасында үсә. 20–100 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы ботаклы. Яфраклары ланцетсыман, аскылары сапчыл, сабактагылары — утырма. Чәчәкләре сары, чук чәчәк төркемендә. Җимеше — грушасыман кузакчык. Май–августта чәчәк ата. Җимешләре июнь–августта өлгерә. Майлы, терлек азыгы үсемлеге.

**ШЕПКӘ́Н** (Brassika campestris), кыр кәбестәсе, әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан кәбестә ыругы берьеллык үләнчел үсемлекләр төре; сидераль һәм май культурасы. Чүп үлән, Төньяк ярымшарның уртача поясында , РФ дә барлык җирдә үсә. Тамыры нәзек, үзәк тамырлы. Сабагы 20–100 *см* биеклектә. Түбәнге яфраклары яшел, каты төкле, күп өлеше лирасыман, калганнары — күгелҗем, йомыркасыман-ланцетсыман, йөрәксыман төбе б-н сабакларны урап ала (яшь яфракларын салат өчен кулланырга ярый). Чәчәкләре сары, чукта утыра. Җимеше — кузакчык, конуссыман очлы, озынлыгы 3–5 *см*. Орлыклары шарсыман, соры кунык б-н кызгылт-көрән төстә; 35–45% шепкән мае бар, аның яртысыннан артыгы физиол. актив май кислоталарыннан тора (олеин һәм линол); 1000 орлыкның авырлыгы 1,5–3,2 *г*. Түбе а.х. терлекләренең барлык төрләре өчен югары аксымлы терлек азыгы концентраты буларак кулланыла. Көзге һәм язгы формалары бар. Баллы үсемлек. ТРда «Восточная» сорты зур булмаган мәйданнарда, башлыча Апас һәм Буа р-ннарында үстерелә.

*Әд.:* Файзрахманов Д.И., Сафиоллин Ф.Н., Низамов Р.М. Ресурсосберегающая технология возделывания масличных культур и производство биотоплива. К., 2007.

**ШЕПШЕҢӘ́Р** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 27 *км* көньяктарак, Мишә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 147 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.дә мәчет була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 736,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 40 ир-ат; 1859 да — 270, 1897 дә — 392, 1908 дә — 443, 1920 дә — 362, 1926 да — 420, 1949 да — 330, 1958 дә — 337, 1970 тә — 365, 1979 да — 307, 1989 да — 224, 2002 дә — 183 кеше.

**ШЕРГИНА́** Илсөя Илгиз кызы (24.7.1948, Казан), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), химия фән. канд. (1983). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Химия-технол. фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү өлкәсе Люберцы ш.) эшли. 1975 елдан Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1983 тән). Хезмәтләре индивидуаль саклану чаралары өчен материалларны һәм алар нигезендә ясалган эшләнмәләрне тикшерүгә карый. ТР Дәүләт бүләге җитештерү процессы шартларында һәм авария очракларында кешене агулы, агрессив матдәләр тәэсиреннән һәм җылылык факторларыннан саклау өчен комплекслы чаралар эшләүдә һәм аларны серияле җитештерүне оештыруда катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**ШЕРЕМЕ́ТЕВ** Василий Петрович (? – 1659, Мәскәү), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1641). Н.В.*Шереметевның* онығы, И.П.Шереметевның энесе. «*Болгавыр заман*» чорында Ялган Дмитрий II ягында була, соңыннан К.Минин һәм Д.М.Пожарский ополчениесенә керә (1611–12). 1620 һәм 1640 елларда Казан төбәгендә: 1623–24 тә Зөя воеводасы, 1647–49 да Казанның 1 нче воеводасы. 1645–46 да Юлбасарлык приказы судьясы. 1654–67 дә рус-поляк сугышында катнаша; 1654 тә Ш. җитәкчелегендәге рус гаскәре Полоцк, Витебск шәһәрләрен ала.

*Әд.:* Барсуков А.П. Род Шереметевых. СПб., 1881. Кн. 4.

*Е.В.Липаков.*

**ШЕРЕМЕ́ТЕВ** Иван Петрович (? — 8.7.1647, Мәскәү), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1634). Н.В.*Шереметевның* оныгы, В.П.Шереметевның абыйсы. «*Болгавыр заман*» чорында 1 нче рус ополчениесендә катнаша (1611); ополчениенең таркалуында төп гаепләрнең берсе, аның җитәкчеләреннән булган П.П.Ляпуновны үтерүдә катнаша. Д.М.Пожарскийның шәхси дошманы. Озак кына вакыт җәбер-золымга дучар була. 1634–36 да Казанда 1нче воевода. 1640 тан Владимир мәхкәмә приказы судьясы.

*Әд.:* Барсуков А.П. Род Шереметевых. СПб., 1881. Кн. 4. *Е.В.Липаков.*

**ШЕРЕМЕ́ТЕВ** Никита Васильевич (? — 1564), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, окольничий (1556), бояр (1557). И.П. һәм В.П.Шереметевларның бабасы. 1547–48 елларда Казанга яуда катнаша, 1548 нең мартында Арча кырында сугыша. *Казанның яулап алынуы* вакытында (1552) патша полкында бояр балалары йөзлегенең сайланган башлыгы була, Казанны камауда һәм морза *Япанча* башлыгындагы татар атлы гаскәрен тар-мар итүдә катнаша. Рус-швед (1554–57) һәм Ливон (1558–83) сугышларында була. Казанда 2 нче воевода (1557–59). Нахакка гаепләнә, Иван IV әмере буенча үтерелә.

*Әд.:* Барсуков А.П. Род Шереметевых. СПб., 1881. Кн. 1. *Е.В.Липаков.*

**ШЕРЕМЕ́ТЕВ** Пётр Васильевич Меньшой (1650 тирәсе — 20.4.1697, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе, бояр (1678). Туганнан туган агасы, В.П.*Шереметевның* улы П.В.Шереметев-Большойдан аеру өчен аны рәсми рәвештә «Меньшой» дип йөртәләр. 1676–79 елларда Псков, Тубыл шәһәрләрендә воевода. 1680–83 тә Казанда воевода. 1682 дә Казан өязенең Кама аръягы өлешенә калмыклар һөҗүмен кире кайтара. 1689 дан Утарлар приказы судьясы.

*Әд.:* Барсуков А.П. Род Шереметевых. Спб., 1899–1905. Кн. 7–8. *Е.В.Липаков.*

**ШЕ́РМАН** Исай Эзрович (28.6.1908, Киев — 13.6.1972, Ленинград), дирижёр, педагог, проф. (1963), РСФСРның атказ. артисты (1940), Карелия АССРның халык артисты (1959). 1931 елда Ленинград консерваториясен (А.Гаук классы) тәмамлый. 1931–37, 1945–49 да — Ленинград Кече опера театры, 1937–45 тә — С.М.Киров исем. Ленинград акад. опера һәм балет театры дирижёры (беренче булып А.Крейнның «Лауренсия» (1939) һәм С.Прокофьевның «Ромео һәм Джульетта» (1940) балетларын куя), бер үк вакытта, 1940–41 дә, Ленинград консерваториясенең Опера студиясе музыка җитәкчесе һәм дирижёры. 1956–58 дә — Горький опера һәм балет театры, в 1958–60 та Петрозаводск муз. драма театры баш дирижёры. 1935 тән симф. дирижёр буларак чыгыш ясый: СССР шәһәрләрендә концерт эшчәнлеге алып бара. 1951–55, 1961–66 да Татар опера һәм балет театрында баш дирижёр. Казанда Ш. җитәкчелегендә «Катерина Измайлова» операсы (Д.Шостакович), «Башмагым» муз. комедиясе (Ж.Фәйзи) һ.б.; беренче тапкыр Н.Җиһановның «Намус» (1953) һәм «Җиңү юлы» (2 нче редакциясе — «Илдар» операсы, 1954) операларын куела. 1938 дән Ленинград, Казан, Горький консерваторияләрендә укыта. Укучылары арасында О.Л.Лундстрем, А.З.Монасыйпов, М.Эрмлер һ.б. бар.

*Әд.:* Дирижёр И.Э.Шерман: Статьи, письма, воспоминания // Из фондов Кабинета рукописей РИИИ. 2002. Вып. 3.

**ШЕРМЕРГО́РН** Илья Матвеевич (1.6.1935, Мәскәү — 9.2.1993, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1979), проф. (1993). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), шунда ук эшли. 1964 елдан СССР ФАнең Органик һәм физик химия ин-тында, 1969 дан Казан вет. ин-тында, химиотерапия бүлеге мөдире. 1984–92 дә «Союзнефтепром» фәнни-җитештерү берләшмәсендә, нефть промыселы җиһазларын коррозиядән һәм биобозылудан химик саклау бүлеге мөдире (1986 дан). 1992–93 тә «Напор» АҖ директоры. Хезмәтләре фосфин к-талары биофункциональ чыгарылмаларының һәм алар нигезендә булдырылган поликонденсатлашкан полимерлар синтезына һәм аларның үзлекләрен тикшерүгә карый. Ш. нефтьне җыю, транспортлау һәм әзерләү системасында нефть промыселы җиһазларын коррозиядән һәм биобозылудан саклау өчен ингибитор-бактерицид үзлекләргә ия булган деэмульгаторларны эшли. Фәнни эшчәнлегенең нәтиҗәләре «Татнефть» АҖдә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 70 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. «Почёт билгесе» ордены, СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә. «Напор» җитештерү берләшмәсе Казан технол. ун-ты студентлары өчен Ш. исем. стипендияне гамәлгә куя (1995–98).

Хезм.: Фосфорсодержащие смешанные полиамиды на основе карбоксильных производных фосфиновых кислот // Высокомолекулярные соединения. 1971. Т. 13, № 10 (автордаш); Синтез непредельных фосфорорганических соединений реакцией триалкилфосфитов с нитроалкенами // Журн. орган. химии. 1975. Т. 45, № 4 (автордаш); Новое направление в реакциях полных эфиров кислот трёхвалентного фосфора с нитроолефинами // Журн. орган. химии. 1982. Т. 52, № 3 (автордаш).

**ШЕРСТНЁВ** Анатолий Николаевич (27.1. 1938, Ташкент), математик, физика-матем. фән. д-ры (1980), проф. (1982), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996), Казан ун-тының атказ. профессоры (2007). 1960 елда Казан ун-тын тәмамлый, Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, ихтималлыклар теориясе һәм матем. стат. бүлеге мөдире (1964–73); матем. анализ каф. мөдире (1974–98), 1998 дән шул ук каф. профессоры. Хезмәтләре нәкоммутатив интеграллауга, метрик фәзаларның ихтималлылык теориясенә карый. Ш. нормалашкан очраклы фәзалар төшенчәсен кертә һәм тикшерә, оператор алгебраларында үзәкләштерелмәгән функционалларга (үлчәүләргә) нисбәтән оператор алгебраларында нәкоммутатив интеграллау теориясен төзи, оператор алгебралары ортопроекторларында чиксез үлчәнешләр һәм зарядлар төзеләшен өйрәнә. Медальләр, ш.и. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: О понятии случайного нормированного пространства // Докл. АН СССР. 1963. Т. 149, № 2; Введение в некоммутативную теорию интегрирования // Итоги науки и техники. Соврем. проблемы математики. Фундам. направления. 1985. Т. 27 (автордаш); Методы билинейных форм в некоммутативной теории меры и интеграла. М., 2008.

**ШЕРСТЮКО́В** Олег Николаевич (27.3.1959, Ставрополь крае Зеленчукская станицасы), физик, физика-матем. фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), шунда ук эшли, радиофизика каф. мөдире (2000 елдан). Хезмәтләре ионосферада радиодулкыннар таралышына, мәгълүмати системаларның физик нигезләренә, мәгълүмати куркынычсызлык мәсьәләләренә карый. Ш. «Циклон-9» ионосфера комплексын ясый (автордаш). Es спорадик катлам чагылуы коэффициентының аналитик моделен эшли; бу катламга кояш-геомагнетик активлыгының һәм метеорологик факторларның йогынтысын ачыклый. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1987), СССР Министрлар Советы бүләге (1988), медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Коэффициент отражения от слоя Es на трассе Москва – Казань // Изв. вузов. Радиофизика. 1988. Т. 31, № 6 (автордаш); Влияние крупномасштабной структуры слоя Es на предельные частоты при наклонном падении // Геомагнетизм и аэрономия. 2001. Т. 41, № 1 (автордаш); Statistical modelling of radiowave propagation under sporadic E-layer influence // Adv. In Spase Research. 2009. V. 43, Iss. 11 (автордаш).

**ШЕРШЕНЕ́ВИЧ** Габриэль Феликсович (1.1.1863, Херсон губ. — 31.8.1912, Мәскәү), юрист, гражданлык хокукы д-ры (1891), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. Казандагы Икенче ир балалар гимназиясен (1881), Казан ун-тын (1885) тәмамлый. 1886 елдан укытучы, 1892 дән сәүдә хокукы һәм мәхкәмә эшләрен башкару каф. профессоры. 1901–02 дә Казан шәһәр думасы гласные, юридик комиссия әгъзасы. Казан юридик җәмгыяте рәисе (1899–1902). Казандагы Мария (беренче) кыз балалар гимназиясенең Попечительләр советы әгъзасы һәм рәисе (1900 дән). Казан коммерция училищесен (1905) һәм Югары хатын-кызлар курсларын (1906) оештыруны башлап йөрүчеләрнең берсе. 1905–07 еллар Рев-циясе чорында либераль иҗтимагый хәрәкәттә актив катнаша, Казан губернасында *Конституцион демократлар партиясе* бүлеген оештыручыларның берсе. Кадетлар партиясенең 2 съездында (1906) ҮК әгъзасы итеп сайлана, партия программасын төзүдә катнаша. Илне конституцион һәм демократик үзгәртеп кору, кадетлар партиясе программасы, Россиядә иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисади тормышны эволюция юлы б-н реформалаштыру турында лекцияләр укый. 1905–06 да актуаль сәяси мәсьәләләргә багышланган хезмәтләр бастыра: «Земство соборы» («Земский собор», 1905), «Халык вәкилләре» («Народные представители», СПб., 1906), «Конституцион демократлар партиясенең гадиләштерелгән программасы» («Программа Конституционно-демократической партии

в общедоступном изложении», М., 1906), «Аграр мәсьәлә» («Аграрный вопрос», М., 1906), «Конституцион монархия» («Конституционная монархия», М., 1906) һ.б. 1 нче Дәүләт Думасы депутаты (1906), кадетлар фракциясе әгъзасы, секретарь иптәше (урынбасары); редакция, җыелышлар ирегә комиссияләренә керә. Приказчикларга нормаль ял бирү хакындагы закон проектын эшләүдә катнаша. Дума куып таратылганнан соң (1908), *Выборг өндәмәсен* имзалый, шуның өчен кулга алына һәм 3 айга төрмәгә ябыла (Мәскәүдәге Таганка төрмәсендә тотыла), мәхкәмә тарафыннан сайлау хокукыннан мәхрүм ителә. 1906–11 дә Мәскәү ун-тының сәүдә хокукы кафедрасында, бер үк вакытта Мәскәү коммерция ин-тының гражданлык һәм сәүдә хокукы кафедрасында; биредә Ш. икътисад бүлегенең беренче деканы булып сайлана. 1911 дә либераль карашлы башка укытучылар б-н бергә халык мәгарифе министры Л.А.Кассо үткәргән сәясәткә протест йөзеннән Мәскәү ун-тын ташлап китә. Мәскәү коммерция ин-тында һәм А.Л.Шанявский исем. Мәскәү шәһәр халык ун-тында укытуын дәвам иттерә. «Мәскәү халык университетлары җәмгыяте» идарәсе әгъзасы һәм рәис иптәше (урынбасары). Россиядә 20 йөз башының әйдәп баручы хокук галимнәреннән берсе. Гражданлык һәм сәүдә хокукы, социол. буенча дәреслекләр авторы; алар күп тапкыр кабат бастырыла һәм бүгенгәчә әһәмияткә ия («Рус гражданлык хокукы дәреслеге» — «Учебник русского гражданского права», 1894; 11 изд., т. 1–2, М., 1914–15; «Сәүдә хокукы курсы» — «Курс торгового права», ч. 1–2, 1888–89; «Социология», М., 1910). Ш. хокук фәлсәфәсе тарихы һәм гомуми хокук теориясенең методологик мәсьәләләре өстендә эшли, хокукый дәүләт һәм киң халык массаларында хокукый аң тәрбияләү тарафдары, юрист-цивилист буларак төп игътибарын АҖләр һәм ширкәтләрнең хокукый практикасын нигезләүгә, сәүдә, көндәшлек, вексель, авторлык хокукы мәсьәләләренә юнәлтә, Россия империясендә хокук системасын реформалауны яклый. Барлык мөлкәтен Казан һәм Мәскәү ун-тларына васыять итеп калдыра; аның акчасы б-н 1913 тә Казан ун-тында Ш. исем. стипендия гамәлгә куела. 2 нче дәрәҗә Изге Анна һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир медальләре б-н бүләкләнә.


Г.Ф. Шершеневич.

Х е з м.: Система торговых действий: Критика основных понятий торгового права. К., 1888; Наука гражданского права в России. К., 1893; История кодификации гражданского права в России. К., 1898; Курс гражданского права: В 2 т. К., 1901–02; История философии права: В 4 вып. К., 1904–05; Общее учение о праве и государстве. М., 1908; Общая теория права: В 4 вып. М., 1910–12.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Г.Ф.Шершеневич: Некролог // Ист. вестн. 1912. №10; Политические партии России. Конец XIX — первая треть XX: Энцикл. М., 1996; У с м а н о в а Д.М. Профессора и выпускники Казанского университета в Думе и Госсовете России. 1906–1917. К., 2002.

*Р.А.Циунчук, Р.Р.Шиһабетдинов.*

**ШЕСТАКО́В** Дмитрий Петрович (29.10.1869, Казан — 17.6.1937, шунда ук), шагыйрь, тәрҗемәче, әдәбият галиме. Казан ун-тын тәмамлый (1903). 1911–22 елларда Казан ун-тында (проф.), 1992 дән Көнчыгыш пед. ин-тында (1925–31 дә бүленеп). «Шигырьләр» («Стихотворения», СПб., 1900) җыентыгы авторы. Гомер, Овидий шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итә. Хезмәтләре антик тарих һәм филологиягә карый.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**ШЕСТАКО́В** Клавдий Александрович (18.4.1934, Архангельск өлкәсенең Нарьян-Мар ш.), генерал-майор (1978). М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне тәмамлый (1968). 1955 елдан СССР Кораллы Көчләрендә: 1957–62 дә совет гаскәрләренең Венгрия Халык Респ-касындагы Көньяк төркемендә, 1962–78 дә мотоукчылар полкы командиры урынбасары, командиры, дивизия командиры урынбасары, дивизия командиры, 1978–80 дә Байкал аръягы хәрби округы кадрлар идарәсе башлыгы, 1980–84 тә совет гаскәрләренең Көньяк төркемендә сугышчан хәзерлек бүлеге башлыгы. 1984–90 да Казан Суворов хәрби уч-щесе башлыгы. Идел буе хәрби округының Казан хәрби аучылык җәмгыяте рәисе (1996–2011). Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен», «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШЕСТАКО́В** Пётр Дмитриевич (27.6.1826, Калуга губ., Масальск өязе Алферьево а. — 24.11.1889, Казан), педагог, тарихчы, филолог, җәмәгать эшлеклесе, яшерен советник (1869). Руханилар катлавыннан. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1846). 1846–47 елларда — Смоленск, 1847–49 да — Тверь, 1849–52 дә Мәскәүнең 4 нче ир балалар гимназиясендә өлкән укытучы. 1852–55 тә Смоленск ир балалар гимназиясендә инспектор. 1855–60 та Смоленск губернасы уч-щеләре директоры. 1860–61 дә Мәскәү ун-тында инспектор. 1861–63 тә Мәскәү уку-укыту округы уч-щеләре инспекторы. 1863–65 тә Казан уку-укыту округы попечитele ярдәмчесе, 1865–83 тә попечитель. Россия Университет уставын эшләүдә катнаша (1863). Ш. җитәкчелегендә Идел буенда әҗнәбиләр өчен белем бирү кертелә һәм киң таралыш ала. Аның башлангычында Казан әҗнәби укытучылар семинариясе (1872), Казан укытучылар ин-ты (1876), Казан татар (1876) һәм Сембер чуаш (1877) укытучылар мәктәбе оештырыла. Ш. эшләгәндә Казан уку-укыту округында Казан шәһәр җәмәгать китапханәсе (1865), Казан вет. ин-ты (1874), 2 ир балалар һәм 12 кыз балалар гимназияләре, 7 кыз балалар прогимназияләре, 10 реаль уч-ще, «укытучылар әзерләү өчен» 8 уку йорты ачыла. Ш.ның «Сембер губернасы Буа өязе мәктәпләре турында» («О школах Буинского уезда Симбирской губернии», СПб., 1867), «Әҗнәбиләр мәгарифе турында тагын берничә сүз» («Еще несколько слов об образовании инородцев», СПб., 1867), «Лопариларны агартучылар архимандрит Феодорит һәм изге Трифон Печенегский» (Просветители лопарей архимандрит Феодорит и св. Трифон Печенегский», СПб., 1868), «Калмыкларда христианлык тарату буенча кайбер мәгълүматлар» («Некоторые сведения по распространению христианства у калмыков», СПб., 1869), «Изге Стефан Великопермский чорының хәзерге көнгә кадәр сакланган бердәнбер истәлеге булган борынгы зырян язмасын уку» («Чтение древнейшей зырянской надписи, единственного сохранившегося до сего времени памятника времени св. Стефана Великопермского», СПб., 1871) хезмәтләре Россия халык мәгарифе мәсьәләләренә багышлана. «Борынгы Маҗар шәһәре турында истәлекләр» («Напоминание о древнем городе Маджаре», 1878), «Алабуга шәһәреннән дүрт чакрымдагы Ананьино авылы янындагы каберлек турында берничә сүз» («Несколько слов о могильнике, находящемся близ деревни Ананьинской, в четырех верстах от г. Елабуги», 1879) хезмәтләрендә Казан төбәге тарихы һәм археологиясенең кайбер мәсьәләләрен карый. Эврепидның «Медея» (1865), «Гипполит, венок несущий» (1870), «Троянки» (1876) трагедияләрен борынгы грек теленнән рус теленә тәрҗемә итә. Геогр. буенча хезмәтләр, көндәлекләр һәм истәлекләр авторы. Изге Гурий бораддәрлеге советы (1867–70), Казан ун-ты карамагындагы укучыларга ярдәм җәмгыяте (1871–83), Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте (1878–83) рәисе. Казан ун-ты (1875) һәм Казан руханилар академиясенең (1875) шәрәфле әгъзасы. Казан мәхкәмә округының шәрәфле җәмәгать судьясы (1880 нән).

Х е з м.: География Смоленской губернии. Смоленск, 1857.

*Әд.:* Ф и р с о в Н.А. Памяти Петра Дмитриевича Шестакова: Мысли его об общественном воспитании в России вообще и о просвещении инородческого населения Северо-восточной России в частности. К., 1891; Р о ж д е с т в и н А. Пётр Дмитриевич Шестаков: Очерк жизни и педагогической деятельности. К., 1907; К а р и м о в а И.А. «Всемилостивейше назначен попечителем Казанского учебного округа...»: П.Д.Шестаков // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2012. № 1.

*И.А.Кәримова.*

**ШЕСТАКО́В** Сергей Петрович (20.7.1864, Казан — 11.11.1940, шунда ук), тарихчы, филолог, Петербург ФА мөхбир әгъзасы (1916). П.Д.Шестаковның улы. Казандагы 2 нче гимназияне (1882), Казан ун-тын тәмамлый (1886). Византия филологиясе белгече, РФА мөхбир-әгъзасы Д.Ф.Беляевның шәкерте. 1890 елдан грек теле һәм әдәбияты буенча приват-доцент, 1900 дән грек теле һәм әдәбияты каф. профессоры; бер үк вакытта, 1906–07, 1909, 1911–19 да Казан ун-тының тарих-филол. ф-ты деканы (ун-тта 1933 кә кадәр эшли, итальян һәм латин телләрен укыта,

1921–22 дә антик социализм тарихы буенча курс укый). 1904–10 да Казан уку-укыту округының Попечительләр советы әгъзасы. Бер үк вакытта, 1906 дан, Югары хатын-кызлар курсларында грек теле һәм әдәбияты укыта, 1911–16 да — директор, курслар бинасы төзелешен җитәкли. 1919 дан Төньяк-Көнчыгыш археол. һәм этнография ин-тының археография бүлеге деканы, гомуми һәм Византия палеографиясе курсын, борынгы телләр, Византия әдәбияты буенча лекцияләр укый. 1920 дән Шәрекъ академиясендә, Борынгы Греция һәм Шәрекъ тарихы буенча лекцияләр алып бара. 1923 тән Шәрекъ пед. ин-тының гомуми тарих кафедрасында, Борынгы Греция тарихы буенча лекцияләр укый, археол.-нумизматика музее мөдире була, 1928 дән штаттан тыш фин теле укытучысы. 1933 тән Казан совет хокукы һәм совет төзелеше ин-тында. 1934–38 дә Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең фәнни хезмәткәре, антик һәм урта гасырлар әдәбияты каталогын төзи. Хезмәтләре Византия тарихына, борынгы грек филологиясенә, б.э.ның 4 йөзе чыганакларына карый. Ш.ның хезмәтләрендә төп игътибар Русь-Византия сәяси һәм мәдәни бәйләнешләренә һәм урта гасырларның элгәреге чорындагы Төньяк Кара диңгез буе тарихына юнәлтелә: «Домостройның Византия тибы һәм аның Сильвестр Домострое б-н охшашлыгы билгеләре» («Византийский тип Домостроя и черты сходства его с Домостроем Сильвестра», «Византийский временник» ж-лында, 1901, т. 8, № 1), «Русьтагы Византия илчесе Мануил Комнин» («Византийский посол на Русь Мануил Комнин», 1913), «Милади буенча VI–X йөзләрдәге Херсонес тарихы турында язмалар» («Очерки по истории Херсонеса в VI–X веках по Р.Хр.», М., 1908) h.б. Аның «Одиссея килеп чыгышы турында» («О происхождении Одиссеи», 1892) һәм «Илиада килеп чыгышы турында» («О происхождении Илиады», 1898) диссертацияләре зур фәнни әһәмияткә ия, аларда мәсьәләнең историографиясе бирелә һәм Гомер поэмалары килеп чыгышының оригиналь концепциясе тәкъдим ителә. Византия хронисты Георгий Монах хроникасы турындагы тикшеренүләр циклында Ш. барыннан да элек әлеге үзенчәлекле әсәрнең чыганакларын ачыклый. Кандид Исаврийский, Либаний, Феофан, Симеон Логофей, Ареф Кесарийский h.б. күренекле Византия авторларының хезмәтләрен анализлый. Иоанн Малала хроникасының славян телләренә тәрҗемәләрен, ш.у. тәрҗемәи хәл әдәбиятын (мәс., Симеон Дивногорецның тормышы) өйрәнүгә аерым игътибар бирә. Б.э.ның 4 нче йөзе грек ораторы Либаний нотыкларын тәрҗемә итә («Либаний нотыклары» — «Речи Либания», т. 1–2, 1914–16).

Х е з м.: О происхождении и составе Хроники Георгия Монаха (Амартола). К., 1892; По вопросу об источниках Хроники Георгия Монаха (Амартола) (4 книга Хроники). СПб., 1892; Кандид Исаврийский. Од., 1894; Греческие лирики. К., 1906; Греческая грамматика с текстами для чтения и упражнений в греческом языке. К., 1907; Лекции по истории Византии. К., 1915.

*Әд.:* И в а н о в Ю. Список учёных трудов проф. С.П.Шестакова (1886–1916) // Уч. зап. Казан. ун-та. 1917. Кн. 3–4; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр.словарь. К., 2002. Т. 1; Ш м е л ё - в а Л.М. Семья Казанских учёных Шестаковых и развитие антиковедения и византиноведения в России (40-е годы XIX в. — 30-е годы XX в.). К., 2010.

**ШЕ́ТНЕВ ЧИРМЕШӘНЕ́** авылы, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әшнәк елгасы буенда. 2010 елда 68 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1602 — 03 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шетнева, Шермышева исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 971 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 342, 1897 дә — 491, 1908 дә — 483, 1920 дә — 565, 1926 да — 581, 1949 да — 573, 1958 дә — 472, 1970 тә — 457, 1989 да — 184, 2002 дә — 113 кеше.

**ШЕХОСТА́НКА** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Кырыкмас елгасының (Иж елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 39,4 *км*, ТР чикләрендә — 6 *км*. Бассейнының мәйданы 506,5 $км^2$. Сарапул калкулыгыннан ага. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Әгерҗе р-ны Комсомолка посёлогыннан 2 *км* көнбатыштарак. Түбән агымында елга тугае сазлыклы. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*. тамагыныкы — 77 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Ш.ның 0,3 тән 23,2 *км* га кадәр озынлыктагы 21 кушылдыгы бар, аларның күпчелеге Удмурт Респ-касы терр-ясеннән ага. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,41$км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 114 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 98 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,36 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты 9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**ШЕШӘНӘ́К** (Cucubalus), канәферчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Бер төре бар — җиләкле Ш. (C. Baccifer). Европа һәм Азиядә таралган. ТР терр-ясендә Көнчыгыш Кама аръягында һәм Кама алдының көньяк өлешендә очрый. Тугайлардагы күләгәле урманнарда, елга буйларында, куаклар арасында үсә. Кыска тамырчалы үсемлек. Сабагы 50–150 *см* озынлыкта, ятма яки аз гына күтәрелмә, нык тармаклы. Яфраклары кыска төкчәле ланцет-йомыркасыман. Чәчәкләре яшькелт-ак, берле, яфрак куентыгында урнашканнар. Җимеше — ялтыравык кара коры җиләк. Май–июньдә чәчәк ата.

**ШЕШМИ́НКА** (Чишмә Кирмәне) авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 19 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 380 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, амбулатория. 1734–35 тә Кама аръягы кальгасы (*Кама аръягы чик сызыгы*) (Шешминка фельдшанецы) буларак нигез салына. Беренче булып Шешминка һәм Алексеев ландмилиция полклары солдатлары, 1753 тән имана җирләре h.б. ташламалар алган отставкадагы (игенче) солдатлар килеп урнаша. 1780 дә авылда 1347 кеше яши. 1831 дә җирле халык хәрбиләрдән дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. 1837–41 дәге П.Д.Киселёв реформасыннан соң, 1843–47 дә Ш. халкының күбесе — элеккеге игенче солдатлар ташламалар саклаган Урал елгасы буена күченә. Буш җирләргә дәүләт крәстияннәре килеп утыра. Халкының төп шөгыле игенчелек, терлекчелек, чүлмәк, тәгәрмәч ясау, күн эшкәртү була. 20 йөз башында Дмитрий чиркәве (1866–71 дә төзелә; архит-ра истәлеге), Халык мәгарифе министрлыгы һәм чиркәү-приход мәктәпләре, су тегермәне, күн з-ды эшли; шимбә базары үткәрелә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4301 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Афонькәсе волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 930, 1889 да — 1542, 1897 дә — 2056, 1910 да — 2389, 1920 дә — 2268, 1926 да — 1893, 1949 да — 1628, 1958 дә — 1411, 1970 тә — 1197, 1979 да — 851, 1989 да — 605, 2002 дә — 471 кеше. Ш. терр-ясендә Кама аръягы кальгасы (1732–36) хәрабәләре сакланган.

**ШЕШУКО́В** Евгений Геннадиевич (16.8. 1939, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1985). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1962), СССР Оборона сәнәгате министрлыгының фәнни-тикшеренү ин-ты-88 дә (Мәскәү өлкәсенең Калининград ш., хәзер Королёв ш.) эшли. 1964 елдан Казан ун-тының гидроаэромеханика кафедрасында, Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында (1968–96): гыйльми секретарь (1974–80) һәм аналоглы модельләштерү лаб-ясе мөдире (1976–80), директор урынбасары (1980–94) һәм фильтрлану теориясе бүлеге мөдире (1989 дан). 1996 дан Казан энергетика ин-тының механика каф. профессоры. Хезмәтләре аэрогидромеханиканың кайтма кырый мәсьәләләренә һәм күзәнәкле мохитләрдәге нәсызыкча фильтрлану теориясенә карый. Ш. нәсызыкча фильтрация мәсьәләләрен чишүнең аналитик һәм микъ-

дари алымнарын эшли. Тикшеренүләрнең нәтиҗәләре эре су гидрокорылмаларда: Рогун һәм Нурек ГЭСларының (Таҗикстан), әл-Багдади (Гыйрак), Тери (Һиндстан) плотиналарының фильтр хисапланышын ясаганда кулланыла. Уйлап табуга авторлык таныклыгы һәм патентлы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О краевых задачах нелинейной анизатропной фильтрации // Докл. АН СССР. 1981. Т. 256, № 31 (автордаш); Фильтрация через пористую преграду на проницаемом основании // Изв. вузов. Математика. 1999. № 10 (автордаш); Фильтрационный расчёт задачи нелинейной фильтрации в неоднородной грунтовой плотине // Энергетика Татарстана. 2007. № 1 (автордаш).

**ШИБАКО́В** Владимир Георгиевич (14.11.1950, Чиләбе өлкәсенең Куса р-ны Злоказово а.), металлар белеме өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1994), проф. (1994). 1972 елда Уфа авиация ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1980 нән Липецк политехник ин-ты укытучысы. 1982 дән Кама инженерлык-икътисад академиясендә (Чаллы ш.), 1985 тә машиналар һәм металларны басым б-н эшкәртү кафедрасын оештыра һәм җитәкли, бер үк вакытта, 1995 тән, проректор, 2007 дән ректор. Хезмәтләре металлар җимерелү механикасына, технол. системотехникага, социоикътисади системаларны тикшерүгә карый. Ш. деформация шартларында металл җимерелү моментын һәм төрен хисаплау, пластик формалар хасил итү өчен нәтиҗәле технол. процессларны системалы проектлау алымнарын эшли. Уйлап табуга 50 дән артык авторлык таныклыгы һәм патентлы бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының медальләре б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2000).

Х е з м.: Реновация деталей пластической деформации. М., 2000; Автоматизация, робототехника и гибкие производственные системы кузнечно-штамповочного производства. М., 2002; Управление технологической металлоёмкостью производства машиностроительных заготовок. М., 2005.

**ШИБА́НОВ** Виктор Константинович (11.9.1918, Уфа ш. — 31.10.1982, Казан), инженер-электрик, «Татэнерго»ның район энергетика идарәсе идарәчесе (1968–78). Ленинград политехник ин-тын тәмамлый (1941), шунда ук эшли (1939–46). 1946 елдан «Туймазаэлектроток» конторасында (Урыссу пос.): Туймазы үзәк электр станциясенең электр цехы башлыгы, контора идарәчесе (1947 дән). Татарстан ХХСның «Урыссуэнерго» район идарәсе баш инженеры (1948 дән), Урыссу ГРЭСы (1957 дән), Казанның 2 нче җылылык-энергетика үзәге (1962 дән) директоры, «Татэнерго»ның баш инженеры (1963–68). Ш. җитәкчелегендә респ-када эшләүче һәм төзелүче электр станцияләренең җитештерү куәтләре киңәйтелә. Зәй ГРЭСының соңгы блогы, Казандагы 3 нче җылылык-энергетика үзәге һәм КамАЗның җылылык-энергетика үзәге сафка баса. Респ-када энергетика системасының билгеләнгән куәте 9 нчы бишьеллыкта (1971–75) 68% ка арта һәм 1976 га 4554 мең *кВт* тәшкил итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, өч «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШИГАЛИ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 20 *км* көнбатыштарак, Солонка елгасы буенда. 2010 елда 112 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 42%, руслар — 35%) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1909–10 да нигез салына. Оешкан көненнән Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1920 дә — 327, 1926 да — 279, 1938 дә — 607, 1949 да — 450, 1958 дә — 510, 1970 тә — 278, 1989 да — 114, 2002 дә — 141 кеше.

**ШИГАЛИ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 26 *км* көнчыгыштарак, Тоша елгасы буенда. 2010 елда 6 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Карланга исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1887 дә ачыла), 4 җил тегермәне, 3 кибет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1340 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Колунец волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1957 нең 30 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 231 ир-ат; 1859 да — 453, 1897 дә — 876, 1908 дә — 1020, 1920 дә — 1109, 1926 да — 784, 1938 дә — 652, 1949 да — 326, 1958 дә — 317, 1970 тә — 258, 1979 да — 127, 1989 да — 65, 2002 дә — 45 кеше.

**ШИГЫЙЛӘ́Р МӘЗҺӘБЕ́** (شعيلر) *исламдагы* ике юнәлешнең берсе, аның тарафдарлары югары хакимиятнең илаһилыгын һәм аның бары тик *Мөхәммәд* пәйгамбәрнең сәхабәсе, дүртенче хәлифә Гали бине Әбү Талиб нәселендәгеләргә генә тапшырылуын, ш.у. барлык мөселманнар кебек үк, шигыйләр дә Мөхәммәднең Аллаһы илчесе булуын, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренең изге булуларын танырлар. Шигыйлек төп биш «баганага» нигезләнә: Аллаһның берлеген тану («тәүхид»); Илаһи гаделлеккә ышану; пәйгамбәрләргә һәм вәхилеккә («нөбүвәт») ышану; имамәткә (дөньяви һәм дини хакимият берләшкән мөселман җәмгыяте б-н идарә итү принциплары); ахирәткә ышану. Гомуммөселман бәйрәмнәреннән тыш Ш.м.ндә шигый имамнарына багышланган дини бәйрәмнәр билгеләп үтелә, имам Хөсәен, әл-Габбас (Кәрбәла ш.) һәм имам Гали (ән-Нәҗҗәф ш.) мәчетләре изгеләрдән санала. Ш.м.ндә имамлык өстенлек итә, ш.у. галәви, друз, зәед җәмгыятьләре бар. Ш.м. башлыча Иранда, Гыйракта, Ливанда, Әзәрбайҗанда һәм Бахрейнда таралган. Татарстанда Ш.м. әзәрбайҗан диаспорасында һәм иранлылар җәмәгатендә гамәлдә. Ш.у.к.: *Сөнничелек*.

*Әд.:* П е т р у ш е в с к и й И.П. Ислам в Иране в VII–XV веках. Л.,1966; П р о з о р о в С.М. Арабская историческая литература в Ираке, Иране и Средней Азии в 7 — середине 10 в.: Шиитская историография. М., 1980; Д о р о ш е н к о Е.А. Шиитское духовенство в современном Иране. М., 1985; Али ибн Абу Талиб (имам; ок. 602–661). Путь красноречия. М., 2007; К о м п а н и Ф. Али ибн Абу Талиб. М., 2010; Р а ш т и Сайид Казим. Основополагающие догматы веры. СПб., 2011.

**ШИГЫ́РЬ ТӨЗЕЛЕШЕ́**, ритмик яктан оешкан һәм метр-үлчәмгә салынган, шуның б-н прозадан аерымлы шигъри сөйләм системасы. Ш.т. телнең ритмик-интонацион төзелеше, башлыча аның фонетик үзенчәлекләре б-н билгеләнә. Телнең фонетик үзенчәлеге, барыннан да элек, шигырьдә иң кечкенә, ләкин төп ритмик берәмлек булган иҗектә, иҗекнең үзлегендә чагыла. Көчле басымлы һәм күчмә басымлы телләрдә басымлы һәм басымсыз иҗекләрнең аермалары нык сизелеп тора. Чагыштырмача тотрыклы һәм йомшак басымлы телләрдә мондый аерма юк дәрәҗәсендә. Озын сузыклар булган телләрдә иҗекләр бер-берсеннән озынлык һәм кыскалык ягыннан аерылалар. Озын һәм кыска иҗекләр барлыкка килүгә ш.у. аларның ачык яки ябык булып килүләре, ягъни сузык яки тартык авазга тәмамлanулары да йогынты ясый. Иҗекләрнең үзлегенә бәйле бу үзенчәлекләр турыдан-туры Ш.т.ндә һәм метрикада чагылыш табалар. Һәр Ш.т. системасында билгеле бер үзлек кенә беренчел ритмик нигез яки доминанта буларак катнаша. Силлабо-тоник системада басымлы һәм басымсыз иҗекләрнең чиратлашуы, тоник системада басымлы иҗекләрнең төрле зурлыктагы юлларда бер үк санда кабатлануы төп роль уйный, антик яки метрик Ш.т.ндә, ш. у. *гаруз*-*да* озын һәм кыска иҗекләр билгеле бер тәртиптә чиратлашалар, силлабик шигырьдә ритмик төзелеш бертөрлерәк озынлыктагы иҗекләр бер үк санда килгән юлларның кабатлануы нәтиҗәсендә хасил була. Теге яки бу милли поэзиядә кулланылган Ш.т.нең характеры яисә төре мәдәни-тарихи традицияләргә һәм чит әдәбиятларның тәэсире б-н бәйле, мәс., Окт. рев-циясенә кадәр гарәп-фарсы поэзиясе тәэсирендә татар классик поэзиясендә гаруз системасы актив кулланыла. Татар теленең фонетик төзелешенә туры килә торган силлабик система татар фольклорында һәм язма шигърияттә элек-электән яшәп килгән төп Ш.т. булып санала (к. *Ирекле шигырь*, *Силлабик шигырь төзелеше*).

*Әд.:* К у р б а т о в Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. К., 2002; Х а т и п о в Ф.М. Әдәбият теориясе. К., 2002; Словарь литературоведческих терминов. М., 1974.

*М.Х.Бакиров.*

**ШИДЛО́ВСКИЙ И.А. ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**, Казандагы җәмәгать файдалануындагы хосусый китапханә. Казан хәрби госпитале комиссары И.А.Шидловский (1822–84) милкендә була. 1860 елларда шәһәрдә иң танылган китапханә. И.А.Шидловский тарафыннан сатып алынган Н.И.*Кунавин китапханәсе* нигезендә 1864 тә ачыла. Төрле белем өлкәләренә караган, аеруча юри-

дик, ш.у. фәнни, белешмә басмалар, матур әдәбият әсәрләре, популяр журналлар б-н баетыла. 1865 тә И.А.Шидловский тарафыннан 1159 китап, 18 журнал исемнәрен үз эченә алган каталог бастырыла («Отечественные записки», «Современник», «Русский вестник» һ.б.). 1868 дә яңа каталог (2031 исемдә) нәшер ителә, уку залы ачыла. 1871 дә каталогта 3060 исемдәге (6 меңгә якын том) басма исәпләнә. Китапханәдә хезмәт күрсәтү түләүле, бәяләр кыйммәт була. 1870 еллар башында Казанда яңа китапханәләр ачылу сәбәпле, И.А.Шидловский үзенең укучыларының бер өлешен югалта, ә аның үз китапханәсен шәһәр җәмәгать китапханәсе б-н берләштерү турындагы тәкъдиме хакимият тарафыннан хупланмый. 1872 дә китапханә И.А.Шерстневага сатыла.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Воспоминания об И.А.Шидловском и его библиотеке в Казани // Агафонов Н.Я. Заволжская вивлиофика. К., 1887. Вып. 1; Ш и ш к и н В.И., Щ е л ы в а н о в а Ж.В. Казанские частные библиотеки для чтения 30–60-х годов XIX века // Библиотека Казан. ун-та: фонды, раритеты, история...: Сб. Статей. К., 1989.

**ШИЙСК НЕФТЬ ЧЫГАНАГЫ́**, Мамадыш р-ны терр-ясендә урнашкан. Татар гөмбәзенең Төньяк күтәрелмәсенең көнчыгышка караган сөзәклегенә туры килә.1965 елда ачыла. 1992 дән эшкәртелә. Сәнәгый нефтьлелеге югары девонның терригенлы (кын) һәм карбонатлы (мендым һәм семилук горизонтлары) токымнары б-н бәйле. 13 ятма ачыкланган, шуның 5 се эшкәртелә. Уртача яту тирәнлеге — 1633 *м* (мендым) һәм 1700 *м* (кын горизонты). Ятмалар буенча нефтьле мәйдан 8,4 тән (семилук) 41,8 млн. $м^2$ га (кын) кадәр тәшкил итә. Типлары буенча ятмалар катламлы гөмбәзсыман һәм структур-литологик. Коллекторлар күзәнәкле һәм кушылы-ярыкланган типта. A+B+C1+C2 категорияле башлангыч чыгарылучы нефть запаслары 4,1 млн. *т* дан артык. Скважиналар дебиты тәүлегенә 35 *т*. Нефтьнең тыгызлыгы 0,829–0,87 $т/м^3$, күкерт күләме 1,5 тән 3,1% ка кадәр, парафин — 4–4,1%. Иярчен газ күләме (моляр өлеш, %): метан 48,4–54,2, этан һәм пропан 31–42. Барлыгы 900 мең *т* дан артык нефть чыгарыла.

*Әд.:* Нефтегазоносность Республики Татарстан: геология и разработка нефтяных месторождений. К., 2007. Т. 2.

**ШИКА́ЛОВ** Николай Сергеевич (18.11.1895, Мәскәү — 31.5.1921, Казан), нәкышьче-график. Нәкышькә Мәскәүдә И.И.Машков остаханәсендә (1913 елдан, бүленеп), 1918 дән Дәүләт остаханәләре каршындагы аның ук остаханәсендә (элекке Мәскәү сынлы сәнгать, скульптура һәм архит-ра уч-щесе), бер үк вакытта, 1918 дән, В.Д.Фалилеевта гравюра техникасына, соңрак шуның ук Сограф (рәссам-гравёрларның профсоюзы) графика остаханәсендә һәм И.Н.Павловта укый. 1919 да Казан дәүләт сәнгать остаханәләренә командировкага җибәрелә. 1920 дә анда графика буенча остаханә оештыра, 1921 дә графика ф-ты деканы. «*Всадник*» графика коллективын оештыручыларның берсе, (рәис), «Всадник» декларациясе авторы И.Н.Плещинскийның урынбасары була. Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә Казанда гравюра, төсле линогравюра һәм ксиллография техникасы торгызыла һәм үсеш ала. Ш. аеруча шәһәр пейзажы, портрет жанрлары, офорт, йомшак лак техникалары куллана. Нәшер ителми калган «Иске Казан» һәм «Миниатюралар» (1921) басмалары өчен төсле линогравюра һәм ксиллография техникасы б-н Казан күренешләрен эшли. «Всадник»ның график альманахларында: 1 нче сан (1920) һәм 2 нче сан (1921), «Шәрекъ орнаментлары» җыентыгында (1920), «Всадник» коллективының 1 нче күргәзмәсе каталогын бастыруда катнаша.

Ш. 1920 елларда Казан сәяси плакатлары башлангычында тора, 1920–21 дә революцион көрәш һәм профсоюзлар хәрәкәте темасына 3 плакат (линогравюра) эшли. Ул Казанда сәнгати сәнгатьне башлап җибәрүчеләрнең берсе, Казан ун-ты коллекциясендә саклана торган Болгар чынаяк кирпечен төсле линогравюрада чагылдыра.

Мәскәү (1919, 1926, 1929), Казан (1920, 1929), Самара (1929) шәһәрләрендә уздырылган күргәзмәләрдә катнаша. Ш.ның эшләре иң эре совет гравюрасы күргәзмәләренә куела: «СССР гравюрасы — 10 ел эчендә» (Мәскәү, 1927), «Рус ксилографиясе — 10 ел эчендә» (Ленинград, 1927); 1990–2000 елларда Казанда (1990, 1992, 1995) һәм Мәскәүдә (2005) күрсәтелә. Шәхси күргәзмәсе (М.Андреевская б-н бергә) рәссамның вафатыннан соң 1921 дә Казанда уздырыла. Әсәрләре Третьяков галереясында 20 йөз графикасы даими экспозициясендә, А.С.Пушкин исем. сынлы сәнгать музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Каталог выставки Н.Шикалова и М.Андреевской. К., 1921; К о р н и л о в П.Е. Н.С.Шикалов: Материалы к словарю Казанских гравёров. К., 1923; Д у л ь с к и й П.М. Казанские современные графики // Гравюра и книга. 1925. № 1/2; Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись, скульптура, графика. М., 1978; Каталог выставки произведений художников Татарии 20–30-х годов. К., 1990; АРХУМАС: Казанский авангард 20-х: Каталог выставки. М., 2005.

*О.Л.Улемнова.*







Н.С.Ш и к а л о в. «Автопортрет». Кәгазь. Линогравюра. 1920; 2. «Казандагы Воздвижение чиркәве». Кәгазь. Төсле линогравюра. 1921; 3. «Казан». Кәгазь. Төсле линогравюра. «Всадник» график альманахыннан бер бит. 1920, №1. Барысы да – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

**ШИКӘ́Р ҖИТЕШТЕРҮ́ СӘНӘГАТЕ́**, азык-төлек сәнәгатенең шикәр чөгендереннән — шикәр комы, шикәр комыннан рафинад җитештерүче пр-тиеләрне берләштерүче тармагы. Эшләүчеләр саны — 1500 кеше (2018). ТРда РФдә эшләп чыгарылган шикәрнең 4,3% ы җитештерелә (2016).

Татарстанда Ш.ж.с. 1950 еллар ахырында, Буа шикәр з-ды, Зәй һәм Нурлат шикәр з-длары (к. «*Зәй шикәр заводы*», «*Нурлат шикәре*») файдалануга тапшырылгач барлыкка килә. Шикәр сезонлы рәвештә, өзлексез технол. процесста җитештерелә. Шикәр эшләүнең барлык операцияләре механикалаштырылган һәм автоматлаштырылган. Заводларда, техник базаны тулысынча яңартып, берничә тапкыр реконструкция уздырыла. 1960 еллар б-н чагыштырганда, чөгендер эшкәртү буенча җитештерү куәтләре 2 тапкыр арта. 1950—60 елларда шикәр з-длары тирәли чимал зоналары булдырыла — якын-тирә районнардагы колхозлар шикәр чөгендере игүгә керешәләр. 1950 дә Октябрь р-нында (хәзер Нурлат р-ны) беренче уңыш җыйнап алына. Заводларга шикәр чөгендере респ-каның 13 районындагы 131 хуҗалыктан җибәрелә. 2016 да сәнәгый эшкәртү өчен чәчелгән чөгендернең мәйданы 63 мең *га*, тамыразыкларның тулай җыемы 2,3 млн. *т* тәшкил итә.

Чөгендердән шикәр җитештерүнең нәтиҗәлелеге чөгендернең шикәрлелегенә һ.б. технол. сыйфатларына бәйле. 2015 тә ТРда заводларда шикәр алу күләме 14,5% ка җитә (1990 да — 12%). Шикәр җитештерү калдыклары терлекчелектә һәм үсемлекчелектә файдаланыла. Ш.ж.с. пр-тиеләрендә «Буа шикәр заводы» ҖЧҖ (икмәк салу өчен чүпрә, коры бөртекле чөгендер түбе чыгара), «Зәй шикәр заводы», «Нурлат шикәре» акц. җәмгыятьләренең (меласса, чөгендер түбе) җитештерү калдыкларын эшкәртү производстволары оештырыла. Дефекация пычрагы — сок чистартылганнан соң аерылган известьле калдык ашлама сыйфатында кулланыла.

1992–2004 тә сезонара чорда респ-ка заводларында Австралиядән, Бразилия, Куба, Мексикадан һ.б. илләрдән чимал буларак китерелгән камыш шикәре эшкәртелә. Аерым елларда (1999, 2003) әлеге чималдан эшләнгән шикәрнең чагыштырма күләме 54% ка җитә, 2004 тә ул 10% тан артмый. Шикәр комы җитештерү 1960 та — 24,7, 1970 тә — 50,8, 2000 дә — 153,6, 2007 дә — 158,5, 2008 дә — 188,2, 2016 да — 260,78 мең *т*

тәшкил итә. Ш.җ.с. ТР халкының шикәр комына ихтыяҗын тулысынча тәэмин итә. Продукция РФнең башка төбәкләренә дә, коры бөртекле чөгендер түбе Балтыйк буе илләренә җибәрелә.

*М.Җ.Гаитов.*

**ШИКӘРЛЕ́ КАЕ́Н** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 54 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1748 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Бәзәкә, Яңа Тупач исемнәре б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1605,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1834 тә — 21, 1859 да — 162, 1870 тә — 275, 1906 да — 392, 1913 тә — 425, 1920 дә — 512, 1926 да — 454, 1938 дә — 504, 1949 да — 248, 1958 дә — 237, 1970 тә — 269, 1979 да — 196, 1989 да — 92, 2002 дә — 71 кеше.

**ШИКША́**, к а р г а н (Empetrum), шикшачалар семьялыгыннан мәңге яшел куакчыклар ыругы. Берничә төре генә (кайбер мәгълүматлар буенча — 18) бар, нигездә, Голарктик һәм Антарктик өлкәләрдә таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре бар — кара Ш. (E. nigrum) Көнчыгыш Кама алдында торфлы сазлыкларда очрый. Яктылык яратучан, нык тармаклы түшәлмә сабаклы. Яфраклары вак, кыяк-эллипсыман, каты, аска таба бөтерелгән читле, сабакны тулысы б-н каплап алганнар. Чәчәкләре берле, алсу яки куе кызыл, 1–3 булып яфрак куентыгында урнашканнар. Җимеше — күгелҗем-кара төстәге шарсыман әчкелтем сусыл җиләк. Май–июньдә чәчәк ата; җимешләре августта өлгерә һәм үсемлектә кыш һәм яз дәвамында саклана. Орлыктан үрчи. Җимешләрендә углеводлар, С витамины, буяу һәм дуплау матдәләре, сумала һәм марганец бар. Ашарга яраклы. Халык медицинасында Ш. җиләкләре нерв системасы авырулары, гипертония очракларында, баш авыртканда кулланыла. Югала баручы төр, ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ШИЛА́НКА** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 7 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шиланка елгасы буенда. 2010 елда 132 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.да земство мәктәбе (1880 ләрдә ачыла), 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1168 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Анатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 159 ир-ат; 1859 да — 417, 1897 дә — 554, 1908 дә — 616, 1920 дә — 616, 1926 да — 648, 1938 дә — 674, 1949 да — 356, 1958 дә — 312, 1970 тә — 246, 1989 да — 109, 2002 дә — 109 кеше.

**ШИЛЛИНГО́ВСКИЙ** Павел Александрович (16.2.1881, Кишинёв — 5.4.1942, Ленинград), график, гравёр, нәкышьче, педагог. Одесса нәфис сәнгать җәмгыятенең Сынлы сәнгать уч-щесендә (1895–1900), Петербург СА каршындагы Югары сынлы сәнгать уч-щесендә Д.Н.Кардовскийда (1901–11 елларда, 1905–06 да бүленеп), В.В.Матэның графика остаханәсендә (1912–14) укый. Акад. мәктәп вәкиле, классик гравюра традицияләрен үстерә. Офорт, ксилография, линогравюра һәм литография б-н шөгыльләнә. Башлыча пейзаж (ш.и. архит-ра), портрет жанрларында эшли, тематик композицияләр ясый, китаплар бизи. 1921 дә Петроград (1924 тән — Ленинград) ВХУТЕМАС-ВХУТЕИНда полиграфия (1924 тән — графика) ф-ты оештыру инициаторларының берсе, 1921 дән проф. һәм декан. 1936–39 дан И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тының нәкышь бүлегендә графика остаханәсен җитәкли.

1922 дән Ш. сәнгать белгече П.Е.*Корнилов* б-н тыгыз бәйләнештә тора. 1924 тә Татарстан респ-ка Үзәк музеенда Ш.ның беренче шәхси күргәзмәсе уздырыла. Казанда аның иҗатына багышлап берничә басма нәшер ителә («Чуфут-Кале» офортлар альбомы, 1926 һ.б.). Казанда Ш. П.Е.Корнилов (ксилография, 1924), Үзәк музей китапханәсе (1926) өчен экслибрислар; ТАССР төзелүгә 10 ел тулу уңаеннан почта открыткалары өчен Казан һәм Алабуга күренешләре (ксилография, 1930); М.К.Корбут тарафыннан төзелгән «Казан дәүләт университеты 125 ел эчендә...» юбилей басмасы өчен «В.И.Ульянов-Ленин 1887 елда гимназияне тәмамлаганнан соң» портретын ясый (ксилография, 1930). 1929 да Казанны сурәтләгән берничә рәсем һәм акварель иҗат итә (Рус музеенда һәм шәхси тупланмаларда саклана). 1905 тән Россиядәге, 1914 тән халыкара күргәзмәләрдә катнаша. Әсәрләре Рус музеенда, Кишинёв, Мәскәү музейларында, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда һ.б.да саклана.

*Әд.:* Д у л ь с к и й П.М., К о р н и л о в П.Е. Каталог выставки офортов и гравюр П.А. Шиллинговского. К., 1924; А д а р ю к о в В.Я. Русские гравёры: П.А. Шиллинговский // Печать и революция. 1925. Кн. 2; Русские гравёры. К., 1926; Г р и ш и н а Е.В. П.А.Шиллинговский. Л., 1980; К л ю ч е в с к а я Е.П. Забытая графическая сюита // Татарстан. 1996. № 9; Г а л е е в И.И. Признание в любви: Казань в работах П.А.Шиллинговского // Казань. 2003. № 5/6.

*О.Л. Улемнова.*

**ШИЛНӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кама елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 39,2 *км*. Бассейнының мәйданы 326,4 *км*². Тукай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Шилнәбаш авылыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Чаллы шәһәренең төньяк чигендә, Боровецкий авылы янында. Елганың түбән агымы Түбән Кама сусаклагычының терәү сулары астында. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 67 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Ш.нең 0,4 тән 13,4 *км* га кадәр озынлыктагы 13 кушылдыгы бар, иң зурлары: Калмаш (12,3 *км*), Бескачанка (13,4 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,64 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык










П.А. Ш и л л и н г о в с к и й. 1. «Казан университеты». Кәгазь. Ксилография. 1929; 2. «Алабуга. И.И.Шишкин яшәгән йорт». Кәгазь. Ксилография. 1930; 3. «Казан. Консистория манарасы». Кәгазь. Ксилография. 1930. Барысы да – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 95 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,046 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Ш. бассейнында суының гомуми күләме 3,7 млн. $м^3$ булган 6 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШИЛНӘБА́Ш** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Шилнә елгасы буенда. 2010 елда 990 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 65%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында татар авылы буларак нигез салына. 18 йөз уртасында Ш. тирәсендәге җирләр Шилнә бакыр эретү з-ды хуҗасы И.И.Небогатовка сатыла, һәм монда рус сарай (1797 дән — удел) крәстияннәре килеп урнаша; алар игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү б-н көн күрә. 20 йөз башында Ш.та чиркәү-приход мәктәбе, тимерче алачыгы, ашлык саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1308 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яр Чаллы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1795 тә — 332, 1870 тә — 359, 1897 дә — 877, 1906 да — 1008, 1920 дә — 930, 1926 да — 784, 1938 дә — 674, 1949 да — 391, 1958 дә — 287, 1970 тә — 312, 1979 да — 474, 1989 да — 783, 2002 дә — 883 кеше.

**«ШИМА́ЛЬ ОЧКЫННАРЫ́»**, журнал. 1943–45 елларда Кеми шәһәрендә (Финляндия), 1945–77 дә Хельсинкида татар телендә нәшер ителә. Нашире — Х.Хәмидулла. Финляндиядәге татар диаспорасына багышлана. Милли мәдәният һәм традицияләрнең үзенчәлекләрен сакларга чакыра. Журналда тарихи-мәдәни, дини тематикага, үсеп килүче буынга эстетик тәрбия бирүгә багышланган материаллар, Коръәннән өзекләр, ш.у. наширнең әдәби һәм публицистик язмалары, «Яңапар тарихы» китабының аерым өлешләре басыла.

**«ШИМА́ЛЬ ЯГЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1918 елның гыйнварыннан 8 апреленә кадәр Петроградта татар телендә нәшер ителә, барысы 8 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — К.Сәгыйд. «Берләшүдә — көч!» лозунгы б-н басыла. Газетада дөньядагы һәм илдәге иҗтимагый-сәяси вакыйгалар, Беренче бөтендөнья сугышы фронтларындагы хәлләр яктыртыла. Петроград һәм аннан читтәге татарлар тормышына, милли үзбилгеләнүнең актуаль мәсьәләләренә, татарларның бергә туплануына (Бологое шәһәре үрнәгендә татарлар тупланып яшәгән районнарда милли-мәдәни мохтарият идеяләрен тарату турында сөйләнә) зур игътибар бирелә. Татарларның иҗтимагый-мәдәни тормышы, аерым алганда, яшьләр клубы оешмасы, хатын-кызларның «Таң җәмгыяте» оешмасы һ.б. б-н таныштыра. Милли матбугат битләрендәге мөһим бәхәсләр (мәс., диннең дәүләттән аерылуы мәсьәләләре буенча «Корылтай» г-тасының «*Чулпан*» г-тасы б-н килешмәве), мәдәният өлкәсендәге вакыйгалар, аеруча Петроградта татар һәвәскәр театры спектакльләре турында даими мәгълүмат бирә. 1918 елгы апрель саннарының берсе Г.Тукайның вафатына багышлана. Редакция большевиклар сәясәтенә каршы ачыктан-ачык чыгыш ясый; газета «советларга каршы пропаганда» өчен ябыла.

*З.З.Гыйләҗев.*

**ШИМА́НСКИЙ** Владислав Владимирович (18.5.1969, Казан), астроном. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), физика-матем. фән. канд. (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1992), шунда ук эшли. 2000 елдан астрофотометрия һәм йолдызлар атмосферасы лаб-ясе мөдире, 2004 тән астрономия кафедрасында. Хезмәтләре йолдызлар атмосферасындагы физик процессларны модельләштерү һәм анализлауга, Галактиканың химик эволюциясенә карый. Дәүләт бүләге «Галактикаларның актив төшләрен, гамма-чайкалуны, рентген космик чыганакларны, астероидларны һәм йолдызларның нечкә спектроскопиясен В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында эшләнгән РТТ-150 һәм аппаратура комплексы ярдәмендә тикшерү» эшләрендә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Атмосферы и спектры звёзд с внешним рентгеновским облучением. Несерая модель // Астрон. журн. 1996. Т. 73 (автордаш); Определение типа двойных систем на основе их фотометрических наблюдений // Астрон. журн. 2008. Т. 85 (автордаш); Масса чёрной дыры в рентгеновской двойной системе LMC X-1 // Астрон. журн. 2016. Т. 93 (автордаш).

**«ШИМБӘЧЕЛӘ́Р»** (гарәп сүзе «шимбә»дән), демократик карашлы татар зыялыларының иҗтимагый оешмасы, әдәбият, театр һәм музыка сәнгатен сөючеләр түгәрәге, максаты — анда катнашучыларның белемнәрен үстерү һәм мәдәни дәрәҗәләрен күтәрү. 1903 елда И. һәм Г.Габитовлар тырышлыгы б-н оеша. «Ш.» составында Ф.Әмирхан, М.Вахитов, Г.Коләхмәтов, Р.Габитова, Ш.Сүнчәләй, Ә.Терегулов, Ә.Терегулова, Казан ун-ты студентлары, Казан реаль уч-щесе укучылары, мәдрәсә шәкертләре була. Шимбә саен утырыш уздырыла. Әдәби әсәрләр уку һәм аларны тикшерү б-н беррәттән татар һәм рус драматургларының пьесалары буенча спектакльләр дә куела (укытучы И.В.Терегулов җитәкчелегендә). Тамашалар өй спектакльләре рәвешендә була. Аларның беренчеләре, Ф.Әмирхан истәлекләренә караганда, 1903 нең кышында ук куела. Тамашачылар даирәсен киңәйтү омтылышы 1906 ның 5 маенда ясала, ягъни спектакльләрнең берсе приказчиклар клубы сәхнәсендә куела. 22 декабрьдә Яңа клубта Н.Кәмалның «Кызганыч бала» драмасы һәм «Гыйшык бәласе» комедиясе буенча спектакльләр дөнья күрә. Бу дата татар проф. театрының туу көне буларак билгеләнә. Спектакльләрдә катнашкан яңа кешеләр арасында З.Габитова-Терегулова, Ш.Мөхәммәдъяров, Г.Сәйфелмөлеков, З.Саинова, Ш.Коләхмәтова, Р.Тенишев була. «Ш.» вәкилләренең күбесе 1910 га кадәр эшләгән «Яшьләр» түгәрәге әгъзалары булып китә («Өч хатын берлән тормыш», «Алдым-бирдем», «Ике гашыйк» (Г.Исхакый), «Бәхетсез егет» (Г.Камал), «Оят, яки күз яше» (Я.Вәли), «Яшь хатын» (Д.Таждаров), «Ярлылык гаеп түгел» (А.Н.Островский) спектакльләре куела).

*Әд.:* Татар совет театры. К., 1975; И л я л о в а И. Театр имени Камала. К., 1986.

*И.И.Илялова.*

**ШИНКАРЁВ** Александр Александрович (20.4.1958, Казакъстан ССР, Актүбә өлкәсенең Журин р-ны 12 нче совхоз бүлекчәсе), туфрак белгече, биол. фән. д-ры (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1980), шунда ук эшли, туфрак белеме каф. профессоры (2009–2017 дә). Хезмәтләре Урта Идел буе урман-дала туфракларының балчыклы-металлы-органик комплексларына карый. Ш. органик матдәләрнең турыдан-туры туфрактан селтеле тоз эремәләре б-н фракцияле экстрагирлауның автоматлаштырылган сыгылмалы колонна алымын эшли. Табигый органик компонентларның органик-смектитлы композитлар формалаштырып, балчыксыл минералларның катламара аралыкларында урнашуын исбатлый.

Х е з м.: О химическом строении гумусовых веществ // Почвоведение. 2001. № 9 (автордаш); Минеральный состав илистой фракции водопрочных агрегатов тёмно-серой лесной почвы // Почвоведение. 2006. № 1 (автордаш); Органические компоненты глино-металло-органического комплекса почв лесостепи (теоретические и экспериментальные аспекты изучения). К., 2007 (автордаш).

**ШИНКЕ́ВИЧ** Алексей Иванович (17.2.1977, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2006), проф. (2007). Казан технол. ун-тын тәмамлый (1999). 1997–2000 елларда «Тәнре» бизнес-инкубаторының бизнес-планлаштыру администраторы. Бер үк вакытта, 1999 дан, Казан технол. ун-тында: каф. профессоры (2007 дән), Корпоратив ин-тның логистика һәм идарә каф. мөдире (2008 дән). Төп фәнни хезмәтләре төбәк икътисады, яңа институциональ караш һәм матем. модельләштерү алымнары кулланып инновацион үсеш мәсьәләләренә карый. ТРның инновацион үсеш концепциясен эшләүдә катнаша.

Х е з м.: Совершенствование институциональной системы инновационного развития регионального промышленного комплекса (на примере РТ). К., 2005; Состояние и перспективы инновационного развития институционально-логистических систем промышленности Республики Татарстан. К., 2006.

**ШИ́ПИНА** Ольга Терентьевна (21.7.1953, Киров өлкәсе Малмыж ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2002), проф. (2005). 1976 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химия физикасына карый. Ш. беренчел целлюлоза сыйфаты б-н целлюлоза нитратлары структур синтезы закончалыклары арасында үзара бәйлелек таба; бу нитратларны

җитештергәндә альтернатив һәм үзара алмаштыручан чимал буларак җитен целлюлозасын куллану перспективасын күрсәтә. Нитрат һ.б. целлюлоза эфирлары, ш.у. аларны эшкәртү продуктларының үзлекләрен яхшырту максатыннан целлюлоза материаллары структурасын юнәлешле үзгәртүнең фәнни-гамәли нигезләрен эшли. Полимер композицияләрдән целлюлозаны һәм аның нитратларын регенерацияләүнең яңа экстракцион алымнарын, регенерацияләнгән продуктларның үзлекләрен модификацияләү һәм аларны утилизацияләүнең ысулларын тәкъдим итә. Ш. эшләгән натрий-карбоксиметилцеллюлозаның конверсив технологиясе, целлюлоза эфирлары үзлекләрен анализлау һәм целлюлозаның структур әверешләрен контрольдә тоту алымнары сәнәгатьтә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 2 патенты бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2011). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование влияния растворов азотной кислоты на свойства льняной целлюлозы // Вестн. Казан. технол. ун-та. 2009. № 6 (автордаш); Закономерности реологического поведения и структурообразования разбавленных растворов нитратов целлюлозы // Пластические массы. 2010. № 3 (автордаш); Свойства и технология изготовления новых видов нитратов целлюлозы специального назначения // Успехи в специальной химии и химической технологии. М., 2010 (автордаш).

**ШИ́ПОВ** Сергей Павлович (5.2.1790, башка мәгълүматларга караганда, 1789, Кострома губ., Солигалич өязе Бельково а. — 25.7.1876, Мәскәү губ., Подольск өязе Старо-Никольское а.), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, инфантерия генералы (1843), сенатор (1846). Дворяннар нәселеннән. 1805–06 елларда Халык мәгарифе департаментында (С.-Петербург). 1806 дан хәрби хезмәттә. 1812 елгы Ватан, 1828–29 еллардагы рус-төрек сугышларында, рус гаскәрләренең 1813–14 тә чит илләрдәге яуларында, 1825 нең 14 декабрендәге декабристлар баш күтәрүен һәм 1830–31 дәге Поляк күтәрелешен бастыруда катнаша. 1817–21 дә Пернов гренадёр полкы, 1821–32 дә Семёновское лейб-гвардия гренадёр полкы командиры. Россиядә яшерен җәмгыятьләрне төзүчеләрнең берсе; Коткару берлеге (1816–19) һәм Иминлек берлеге (1818–19) әгъзасы. 1832–37 дә генерал-кригс-комиссар (илнең кораллы көчләрен матди яктан тәэмин итү өчен җаваплы чиновник), 1837 дән Хәрби министрлыкның Хәрби советы әгъзасы. Бер үк вакытта, 1837–40 та, Польша Патшалыгының эчке һәм рухани эшләр һәм халык мәгарифе буенча хөкүмәт Комиссиясе баш директоры, 1838–40 та Варшава хәрби губернаторы. 1841–46 да гражданлык эшләрен дә идарә итүче Казан хәрби губернаторы. 1842–43 тә Казан губернасында «бәрәңге фетнәләре»н (крәстияннәрнең бәрәңге утыртуга каршы чыгышлары) бастыра. Төзелеш ком-ты рәисе булгач, Казанны 1842 елгы янгыннан соң торгызу эшләрендә җитәкчелек итә. Ш. җитәкчелегендә Казанда үзәк урамнар тигезләнә һәм аларга таш түшәлә, бульварлар булдырыла; тыкрыклар урынына киң урамнар сузыла; Николай сәүдә мәйданы һәм таш түшәлмәле юллар төзелә, Мунча күле күмелеп, Черек күл тирәсе төзекләндерелә, шәһәр б-н Бишбалта бистәсе арасында дамба, Кремльдә губернатор сарае, дворяннар җыены, почтамт, театр, руханилар академиясе биналары салына башлый; күпсанлы административ, җәмгыяви һәм хосусый йортлар төзелә; шагыйрь Г.Р.Державин һәйкәле корыла башлый һ.б. Ш. Николай исем. (1844), Юнысовлар (1844) һәм Александра исем. (1845) ятимханәләре ачылуга булышлык итә. 1842 дә Казан руханилар академиясен торгызуга ярдәм күрсәтә. Ш. башлангычында «Казанские губернские ведомости» г-тасы үзгәртеп корыла (1843 тән атна саен чыга башлый, махсус кушымтасы — «Прибавления» нәшер ителә), 1нче Казан а.х. күргәзмәсе (1845) уздырыла. 1846–57 дә Сенатның Мәскәү департаментларында. Хезмәтләре дәүләт идарәчелегенә, рус-поляк мөнәсәбәтләре тарихына карый; хатирәләр яза. Казан икътисадчылар җәмгыяте рәисе (1842–46). Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә.


С.П. Шипов.

Х е з м.: Польское племя в среде народа славянского. СПб., 1844; Взгляд на историю Западной Руси. СПб., 1848.

*Әд.:* Москвич. Генерал-адъютант, генерал от инфантерии С.П.Шипов: Материалы к биографии // Московские ведомости. 1876. 27 июля, 3, 13–14 авг.; З а т в о р н и ц к и й Н.М. Память о членах Военного совета: Портреты и биографические очерки. СПб., 1907; Д о л г о в Е.Б. Строитель по призванию: Казанский губернатор С.П.Шипов // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2003. № 1/2.

*Е.Б.Долгов.*

**ШИРӘМӘ́Т** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнбатыштарак, Уратма елгасы буенда. 2010 елда 1051 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Ат сбруе җитештерү ф-касы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Покров Божией Матери храмы. Сәүдә һәм торак төзелеше комплексы — 19 йөз — 20 йөз башы архит-расы истәлеге. 17 йөз ахырыннан Уратма исемле татар авылы буларак билгеле. 18 йөзнең 2 нче яртысында алпавыт С.В.Шереметев татар морзасы Өркиевтән Уратма авылын һәм тирә-як җирләрне сатып ала һәм монда Түбән Новгород, Орёл губерналарыннан рус крәстияннәрен китертеп утырта. Яңа авыл Богородский дип йөртелә башлый (1917 гә кадәр шушы исемен йөртә, совет чорыннан Ш. дип атала). Халкы игенчелек, терлекчелек, күн эшкәртү, ат дирбиясе, чүлмәк ясау, кирпеч сугу, сәүдә б-н көн күрә. 1860 елларда Богородскийда табиб Н.Анцыфиров шифаханә ача, анда туберкулёз б-н авыручыларны кымыз б-н дәвалыйлар. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Богородица чиркәве (1834 — 43), 3 иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, 2 земство мәктәбе (1866 һәм 1877 дә ачыла), земство хастаханәсе, ссуда-саклау ширкәте, 31 тире эшкәртү һәм 2 кирпеч з-ды, 3 киез басу йорты, 5 тимерче алачыгы, 1 су тегермәне, 5 кайры төйгеч, трактир, 7 сырахanә, 1 казна шәраб һәм 24 вак-төякләр кибете була; дүшәмбе базары, 24 июньдә Ивановка ярминкәсе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3009,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Богородский волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1782 дә — 92 ир-ат; 1859 да — 2553, 1897 дә — 2110, 1908 дә — 3660, 1920 дә — 3712, 1926 да — 3060, 1949 да — 1702, 1958 дә — 2741, 1970 тә — 2326, 1979 да — 1908, 1989 да — 1400, 2002 дә — 1222 кеше.

**ШИРӘМӘ́Т РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1930 елның 10 августында оештырыла. Үзәге — Ширәмәт авылы. 1920 гә кадәр район терр-ясе Казан губернасының Чистай өязенә һәм Уфа губернасының Минзәлә өязенә керә, 1920 дән ТАССРның Чистай һәм Минзәлә кантоннарында, 1921 дән ТАССРның Чистай һәм Чаллы кантоннарында. Оешкан көненнән Ш.р.нда 41 авыл советы, 113 торак пункт исәпләнә, аларда 48506 (руслар — 35672, татарлар — 12277, башка милләтләр — 557) кеше яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1342 *км*², халык саны — 45,4 мең кеше; 30 авыл советы, 88 торак пункт керә. 1956 да районның мәйданы — 1456 *км*² була, 25 авыл советын һәм 89 торак пунктны берләштерә. 1960 та район 1475 *км*² җир били, 10 авыл советы, 78 торак пункт исәпләнә. 1963 нең 1 февралендә Ш.р. таркатыла, биләмәсе Чаллы һәм Чистай р-ннарына бирелә.

**ШИРБӘ́Т** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 26 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 4 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 1690 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Михайловский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, йон-тукыма мануфактурасы б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Михаил Тверской чиркәве (1761 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство (1868 дә ачыла, 1883 кә кадәр — чиркәү-приход мәктәбе) һәм а.х. мәктәбе, 6 җил тегермәне, тимерче алачыгы, ярма яргыч, йон-тукыма ману йорты, 1 зур һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 401 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ширбәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апр. — 1991 нең 4 окт. Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 358 ир-ат; 1859 да — 1070, 1897 дә — 1150, 1908 дә — 1424, 1920 дә — 1559, 1926 да — 1176, 1938 дә — 669, 1949 да — 428, 1958 дә — 688, 1970 тә — 325, 1979 да — 151, 1989 да — 33, 2002 дә — 33 кеше.

**ШИРБӘ́Т ХӘЗИНӘСЕ́**, җиз коелмалар җыелмасы. 1964 елда Спас р-ны Ширбәт авылы янында П.Н.Старостин тарафыннан ачыла. Куйбышев сусаклагычы сулары юган Ширбәт авыллыгы терр-ясендә (мәйданы 4,5 *га*) бакыр кою остаханәләре калдыклары, *Имәнкискә культурасына* нисбәтле керәч, тимер һәм бронза әйберләр табыла. Ш.х. бакыр, цинк, кургаш һәм аккургаш катнашмасыннан торган, таякчыклар рәвешендәге 70 коелмадан гыйбарәт (һәрберсенең озынлыгы 18 *см* чамасы, диаметры 1 *см* га кадәр, авырлыгы 98 *г* нан 106 *г* га кадәр). Охшаш коелмалар Кама буендагы кайбер археол. истәлекләрдә очрый. Фаразланганча, 5–7 йөзләрдә коелмалар акча ролен башкарганнар.

*Әд.:* Сидоров В.Н., Старостин П.Н. Остатки раннесредневековых литейных мастерских Щербетьского поселения // Советская археология. 1970. № 4; Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987; Мухамадиев А.Г. Древние монеты Казани. К., 2005.

*П.Н.Старостин.*

**ШИРИ́Н**, 15–17 йөзләрдә Казан, Кырым һәм Касыйм ханлыкларында идарәче ыругларның берсе. Башка ыруглар (Аргын, Барын, Кыпчак) арасында иң дәрәҗәлесе һәм көчлесе. Ыруг башлыгы, кагыйдә буларак, хан диваны башлыгы — бәкләр бәге вазифасын били. Йогынтыларыннан файдаланып, Ш. ыругы вәкилләре үз дәүләтләренең сәяси тормышында әйдәп баручылар ролен башкарырга омтылалар. Казан ханлыгында Ш. ыругының иң күренекле вәкилләре — *Шаһгали, Җангали һәм Сафагәрәй* ханнар сараенда зур урын тоткан *Булат Ширин*, Шаһгали хан хөкүмәтенең бәкләр бәге *Нурали бәк*.

*Әд.:* Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

*И.Л.Измайлов.*

**ШИРКӘ́Т** (гарәп. شركت), ике яки берничә зат тарафыннан, килешү нигезендә үз кертемнәрен берләштереп, уртак эшчәнлек һәм табыш алу яки башка максатларда хокукый җирлектә төзелгән оешма.

Татарстан терр-ясендә беренче Ш.ләр 19 йөз ахырында — 20 йөз башында барлыкка килә (эшчәнлекләрен сәнгать, сәүдә, а.х. өлкәсендә алып баралар). 1908 елда Г.Кариев җитәкчелегендәге татар артистлары төркеменең Кавказдагы гастрольләрен уздыру өчен *Казан-Кавказ мөселман артистлары ширкәте* төзелә. 1920 еллар ахырында — 1930 еллар башында а.х.нда җитештерү кооперациясенең бер формасы буларак *Җирне бергәләп эшкәртү ширкәте* барлыкка килә. 1922 дә ТАССРда 109, 1925 тә — 183, 1926 да — 199 а.х. Ш.е һәм 54 посёлок Ш.е була. Крәстиян хуҗалыклары кооперативларының күпчелеге кредит һәм сатып алу-сату Ш.ләре нигезендә төзелә. Һәр Ш.кә уртача 331,6 хуҗалык һәм 1072 кеше туры килә. 1928 дә 140 җирне бергәләп эшкәртү Ш.е эшли. Коллективлаштыру елларында бу ширкәтләрнең күпчелеге колхоз итеп үзгәртеп корыла.

Ш.ләрнең төп төрләре: тулы Ш., ышанычы нигезендәге (коммандит) Ш., өстәмә җаваплылыктагы яки җаваплылыгы чикләнгән Ш. Башлыча, *бакчачылык ширкәтләре*, торак хуҗалары Ш.ләре а.х., сәүдә, гараж һәм торак төзелеше тармакларында оештырылган Ш.ләр киң тарала. Тулы Ш.тә катнашучылар Ш. исеменнән эшмәкәрлек б-н шөгыльләнәләр һәм аның бурычларын шәхси мөлкәтләре б-н түләү җаваплылыгын үз өсләренә алалар. Тулы Ш.ләр гамәлгә куючылар килешүе нигезендә төзелә һәм эшчәнлек алып бара. Килешүчә якларның берсе нииндидер сәбәп б-н Ш.тән чыкса, калган әгъзалар ризалыгы б-н килешү үз көчендә калдырыла.

Ышанычы нигезендәге Ш.тә аның әгъзалары Ш. бурычларын шәхси мөлкәтләре б-н түләүне үз өсләренә ала алалар, ләкин шул ук вакытта арада тулы җаваплылыктагы ширкәтчеләрдән аермалы буларак, Ш. эшчәнлеген куркыныч астына куюдан үз кертемнәре нисбәтендә җаваплылык тотучы һәм эшмәкәрлек эшендә катнашмаучы бер яки берничә коммандист булырга мөмкин. Тулы ширкәтчеләр генә коммандист Ш.е исеменнән эш йөртә һәм килешү төзи алалар.

Җаваплыгы чикләнгән Ш. кредиторлар алдында фәкать үз милке б-н генә җавап тота, кредиторларның таләбе ширкәт әгъзалары мөлкәтенә кагылмый. Капитал пайларга бүленә. Пайны түләгәндә Ш. әгъзаларына Ш. рөхсәтеннән башка башка затларга сату тыелган пайчы таныклыгы тапшырыла. 1990 елларда бакчачылык Ш.ләреннән башка торак хуҗалары Ш.ләре — күп фатирлы йортларда фатир хуҗаларын берләштерүче, күчемсез милек комплексы б-н идарә итү, аны эксплуатацияләү, куллану, закон тарафыннан билгеләнгән чикләрдә уртак милектән файдалану өчен коммерциячел булмаган оешмалар киң тарала. 2010 ның 1 гыйнварына ТРда 10 меңгә якын Ш., ш.и. 5900 торак хуҗалары Ш.е, 1510 бакчачылык Ш.е, 1 меңнән артык сәүдә Ш.е һ.б. исәпләнә.

**«ШИРКӘ́Т»**, татар театр труппасы. 1915 елда Оренбург шәһәрендә актёр һәм реж. В.Мортазин-Иманский тарафыннан оештырыла. Труппа составында — М.Мутин, Н.Сакаев, Г.Мангушев, Ф.Сәмитова, С.Байкина, Н.Таждарова, М.Иманская; соңрак — Ф.Ильская, Х.Әбҗәлилов, Ф.Камалова, Камал I. «Ш.» иҗаты *«Сәйяр»* труппасы тарафыннан формалаштырылган һәм нигезләнгән традицияләрне дәвам итә һәм үстерә; «Ш.»нең күпчелек вәкилләре дә шушы труппадан чыга. Репертуарын «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре», «Бәхетсез егет» (Г.Камал); «Фәхретдиннең кайгысы» (Н.Вәзиров), «Мөгаллимә» (Г.Исхакый) пьесалары, «Ул булмаса — башкасы» (У.Хаҗибәков), «Денщик Хыр-мыр» (С.Мөэзгайни), «Ватык көзге янында», «Би-кә-кә» (М.Фәйзи) муз. комедияләре; чит ил драматургиясеннән — «Ирексездән табиб» («Лекарь поневоле», Ж.-Б.Мольер), «Әлмансур» («Альманзор», Һ.Һейне), «Хөкемдә хаталык» («Судебная ошибка», А.Деннери); рус классикасыннан «Өйләнү» («Женитьба»), «Ревизор» (Н.В.Гоголь) әсәрләре һ.б. тәшкил итә. «Ш.» труппасы тарафыннан беренче тапкыр «Хаҗи әфәнде өйләнә» пьесасы (Ш.Камал, 1917) һәм «Галиябану» мелодрамасы (М.Фәйзи, 1917 нең 19 марты) сәхнәләштерелә; «Мещаннар» («Мещане», М.Горький; 1918 нең марты) пьесасы буенча спектакль күрсәтелә. Гражданнар сугышы башлану б-н, «Ш.»нең күпчелек актёрлары фронт театр бригадаларына күчә, 1918 нең июлендә труппа таркала.

*Әд.:* Мортазин В., Чәнәкәй Т. Татар театры тарихыннан. М., 1926; Гобәйдуллин Х. Оренбург татар театры // Татар совет театры. К., 1975; Мәхмүтов Һ. Оренбург татар театры // Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988.

*И.И.Илялова.*

**ШИРО́КОВ** Александр Петрович (21.12. 1926, Казан — 29.9.1998, шунда ук), математик, геометр, физика-матем. фән. д-ры (1967), проф. (1968), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1979). П.А.*Широковның* улы. 1949 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, геом. каф. профессоры (1968 дән), чагыштырмалылык теориясе һәм гравитация (1970–75), геом. кафедралары мөдире. Хезмәтләре бипланар фәзалар геометриясенә, аффин дифференциаль геометриягә, дифференциаль күптөрлелекләрдә структуралар теориясенә, Вейльнең орынма катламланулар геометриясенә, нәевклид геометриясенә карый. Ш. ирекле ассоциатив коммутатив алгебралар б-н берәмлекнең аффин бәйлелеге күптөрлелекләренең гомуми теориясен үстерә. «Геометрия буенча семинар хезмәтләре» («Труды геометрического семинара», 1979–94, 11–22 чыг.) һәм «Лобачевский истәлегенә багышлана» («Памяти Лобачевского посвящается», 1992, 1, 2 чыг.) җыентыклары мөхәррире. П.А.Широковның симметрик фәзалар геометриясенә багышланып тәмамланмаган бер төркем хезмәтләрен, ш.у. лекцияләре конспектларына нигезләнгән «Аффин дифференциаль геометрия» («Аффинная дифференциальная геометрия», М., 1959; немецчага тәрҗәмәсе — «Affine Differentialgeometrie», Lpz., 1962) монографиясен басмага әзерли

Хезм.: Об одном типе G-структур, определяемых алгебрами // Тр. геометр. семинара. М., 1966. Т. 1; Пространства над алгебрами. К., 1985 (автордаш); Пространства над алгебрами и их применение // Итоги науки и техники. Совр. математика и её приложение. 2002. Т. 73.

*Әд.:* Шапуков Б.Н. Александр Петрович Широков, 1926–1998. К., 2003; Фомин В.Е., Шурыгин В.В. Очерк научной и педагогической деятельности А.П.Широкова // Уч. зап. Казан. ун-та. 2008. Т. 150, кн.1.

*В.В.Шурыгин.*

**ШИРО́КОВ** Пётр Алексеевич (28.1.1895, Казан — 26.2.1944, шунда ук), математик, геометр, физика-матем. фән. д-ры (1936). *Казан геометрия фәнни мәктәбенә* нигез салучы. 1936 елда диссертация якламый торып физика-матем. фән. д-ры дәрәҗәсен ала. Математиклар династиясен (к. А.П.*Широков*, Е.А.*Широкова*) башлап җибәрүче. 1918 дә Казан ун-тын тәмамлый, 1920 дән шунда ук эшли: проф. (1930 дан), матем., геом. кафедралары мөдире (1933, 1934–44), физика-матем. ф-ты деканы (1941–43); бер үк вакытта шәһәрнең политехник, пед. һәм авиация ин-тларында укыта. Хезмәтләре нәевклид геометриягә, төркемнәр теориясенә, тензор анализга карый. Геом. тикшеренүләрдә Ш. тен-



П.А. Широков.

зор анализ алымнарын куллана, даими кәкрелек фәзасы үзлекләрен билгели, үзлекләре буенча даими кәкрелек фәзаларына якын булган гомуми Риман фәзалары классларын (ш.и. симметрик фәзаларны) аерып ала һәм тикшерә. А-фәзаларны тикшерүне башлап җибәрә (1925), чит илдә алар бары 1933 тә генә Келер күптөрлелекләре буларак мәгълүм була. Ш. ш.у. Киппенхан кәкрелеген беренче булып тасвирлый (1934–35; 1951 елдан мәгълүм). Француз математигы Э.Картанның «Lecons sur la theorie des spineurs» (P., 1938) исемле китабын русчага тәрҗемә итә һәм бастырып чыгара («Спинорлар теорисе» — «Теория спиноров», М., 1947), ш.у. бу авторның аффин, проектив һәм конформ бәйләнгән фәзалары буенча хезмәтләрен (өстәмәләр һәм төгәлләмәләр б-н) тәрҗемә итә. Ш. — Н.И.Лобачевский әсәрләренең тулы җыелмасы мөхәррирләреннән берсе. Ул бөек галимнең заманында немец һәм француз телләрендә чыгарган хезмәтләрен русчага тәрҗемә итә; Н.И.Лобачевский исем. бүләк бирү буенча комиссия әгъзасы (1927, 1937). 1930 елларда матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тын оештыручыларның берсе, андагы геом. бүлеген җитәкли; Казан ун-тының геом. кабинеты китапханәсен комплектлауда, «Известия Физико-математического общества при Казанском университете» ж-лына кергән мәкаләләрне редакцияләүдә катнаша.

Х е з м.: Аффинная дифференциальная геометрия. М., 1959 (автордаш); Тензорное исчисление. К., 1961; Избранные работы по геометрии. К., 1966; Краткий очерк основ геометрии Лобачевского. М., 1983.

*Әд.:* Н о р д е н А.П. Обзор главнейших работ П.А.Широкова // Изв. Казан. физ.-мат. об-ва. Сер.3. 1945. Т. 13; История отечественной математики. Киев, 1968. Т. 3; Л а п т е в Б.Л., Ш и р о к о в А.П., В и ш н е в с к и й В.В. Пётр Алексеевич Широков, 1895–1944. К., 2001.

*В.В.Шурыгин.*

**ШИРО́КОВА** Елена Александровна (14.5. 1951, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (2006). П.А.*Широковның* оныгы, А.П.*Широковның* кызы. 1973 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, гомуми матем. каф. мөдире (2009 дан). Хезмәтләре эластиклык теориясенең кырый мәсьәләләренә, кайтма кырый мәсьәләләргә карый. Lp асфәзасындагы w'(s) өчен кайтма кырый мәсьәләләрнең чишелүчәнлеген исбат итә, җисемнәрнең бер классы өчен өч үлчәнешле куелышта эластиклык теориясенең төп мәсьәләләрен сплай-интерполяцион чишү алымын эшли.

Х е з м.: О некоторых операторах, не выводящих из класса функций однолистных в круге // Изв. вузов. Математика. 1984. № 6; Решение второй основной задачи теории упругости для плоскости с двоякосимметричным вырезом, имеющим два нулевых угла // Прикладная математика и механика. 1997. Т. 61, № 2 (автордаш).

**ШИРО́КОВА** Наталия Александровна (21.8.1900, Сембер губ. Алатырь ш. — 27.4.1978, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (1969), проф. (1972). Шәрекъ-пед. ин-тын (1924), Казан. пед. ин-тын тәмамлый (1938). 1925 елдан Казанда Хезмәтне фәнни оештыру ин-тында, 1933–36 да лаб. мөдире. 1939–40 та Казан пед. ин-тында. 1942–76 да Казан ун-тында, 1960–66 да рус теле һәм гомуми тел белеме каф. мөдире. Хезмәтләре тарихи синтаксиска һәм хәзерге рус теле синтаксисына карый. Чагыштырма мөнәсәбәтләрне белдерүче тел конструкцияләрен, катлаулы кушма җөмләләрне, күпкомпонентлы синтаксик конструкцияләр барлыкка килү закончалыкларын өйрәнә. Синтаксик теркәгечле чагыштыру категориясе концепциясен, чагыштырма конструкцияләр типологиясен эшли. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Типы синтаксических конструкций с сравнительным союзом в составе простого предложения. К., 1960; Из истории предложных конструкций, выражающих сравнительно-сопоставительные отношения. К., 1963; Из истории союзных конструкций, выражающих отношения сравнения. К., 1966.

*Әд.:* А н д р а м о н о в а Н.А., Х а м з и н а Г.Н. Наталия Александровна Широкова, 1900–1978. К., 2003. *К.Р.Галиуллин.*

**ШИРЯ́Й** Иван (16 йөз), рус архитекторы. Патша Иван IV күрсәтмәсе б-н 1556 елда Псков төзүчеләре җитәкчесе итеп *Казан Кремленең* яңа диварын һәм корылмаларын төзергә җибәрелә. Ул И.Я.Постник б-н бергә Кремльнең Көньяк өлеше таш диварын һәм аның Спас, Көньяк-көнбатыш, Көньяк-көнчыгыш, Тайницкий, Воскресение манараларын кора. Алар тарафыннан Кремльдәге Благовещение соборы (1561–62), Зөядә Успение монастыренең Никола трапеза чиркәве (1556) һәм Успение соборы (1560–61) төзелә.

*Әд.:* А й д а р о в С.С. Архитектурное наследие Казани. К., 1978; О с т р о у м о в В.П. Казань: Очерки по истории города и его архитектуры. К., 1978.

**ШИ́ТИКОВ** Борис Владимирович (6.10.1905, Орёл губ., Ливны өязе Югары Любовина а. — 1982, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. канд. (1940), проф. (1963). 1930 елда Мәскәү Н.Э. Бауман исем. югары техник уч-щене тәмамлый. 1930–41 дә һәм 1945–51 дә Мәскәү тимер юл транспорты инженерлары электромеханика ин-тында эшли, гамәли механика каф. мөдире (1945 тән). 1951 елдан (бүленеп) Казан химия-технол. ин-тының механизмнар һәм машиналар теориясе кафедрасында, проф.-консультант (1971–76). 1960–66 да Казан а.х. ин-тында, машина детальләре һәм графика каф. мөдире (1963 тән). Хезмәтләре механизмнар һәм машиналар конструкциясе һәм теориясе нигезләренә, әйләнмә детальләрне баланслау мәсьәләләренә карый. Ш. машиналар төзү мәсьәләләрен: фәзаи механизмнарны, тешле тапшыргычларны, машиналарны тигезләндерүне, кече җисемнәр инерциясе моментларын, подшипник узеллары эше режимын билгеләүне һ.б.ны тикшерү б-н шөгыльләнә. Роторларны тигезләндерүнең теоретик нигезләрен булдыручыларның берсе. Ш. динамик баланслау өчен резонанс типлы станокларны («Шитиков станоклары») эшли. Уйлап табуга авторлык таныклыклары бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, башка орденнар; медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Динамическая балансировка роторов. М., 1951.

**ШИФАЛЫ́ ЛӘМНӘ́Р**, төче һәм тозлы сулыкларның лайлалы утырымнары, сазлыкларның торфлы утырмалары, майсыман консистенцияле псевдовулканик балчыксыл токымнар; җылытылган халәттә ванналар һәм аерым урыннарга аппликация рәвешендә дәвалау максатларында кулланыла. Геол. процесслар йогынтысында табигый шартларда барлыкка килә. Ш.л.нең составында диаметры 0,0001 *мм* дан зуррак (балчыксыл һәм комсыл, кальцит, доломит, гипс кристаллиглары) булган каты кисәкчекләрне берләштерүче кристаллик скелет; 0,0001 дән 0,00002 *мм* га кадәр үлчәмле кисәкчекләрдән торучы коллоидлы комплекс (тимер сульфиды, тимер гидросульфиды, алюминий һәм тимер гидрооксидлары, кремний к-тасы, гумус, бик вак балчыксыл кисәкчекләр); ләм эремәсе (су, суда эрегән тозлар һәм органик матдәләр, кайвакыт биол. актив газлар) бар. Ш.л. биоколлоидлар барлыкка китерүче күптөрле микроорганизмнардан тора, аларның тереклек эшчәнлеге продуктлары исә микробларга каршы тору үзлегенә ия. Ш.л.нең төп үзлекләре: йомшаклык, үзлелек, ябышкаклык, югары җылысыешлылык, җылы үткәрүчәнлек.

Ш.л. суда эрүче тозларның (төче су, түбән, уртача һәм югары минеральләшкән сулар) һәм сульфидларның күләме, мохит реакциясе (pH), ләм эремәсенең ион составы, ш.у. көллелек һәм көл составы (торфлар һәм сапропельләр) буенча классификацияләнә.

БДБдә Ш.л.нең 500 дән артык: торфлы (органик), сапропельле (органик-минераль), лайлалы һәм псевдовулканик (минераль) чыганаклары ачыкланган. Аеруча билгеле чыганаклар: торфлы ләмнәр — Мәскәү өлкәсендә Татищево һәм Юховка, Рязань өлкәсендә — Сапожок; сапропельле ләмнәр — Уралда Молтаево күле, Карелиядә Габозеро, Смоленск өлкәсендә Мутное күле һ.б. Югары минеральләшкән күлләрнең лайлалы ләмнәре күбесенчә тозлы сулыкларның: Ставропольдә — Тамбукан, Әстерхан өлкәсендә Танаки һ.б.ның утырмалары булып тора. Сопка ләмнәре — газ һәм этем сулары б-н тектоник ярыклардан атылучы минераль балчыксыл токымнар; нефть һәм газ ятмалары булган өлкәләрдә (Көньяк Сахалин) таралганнар

Ш.л. терәк-хәрәкәт әгъзалары, нерв, ашкайнату, кан тамырлары системасы авыруларын, ш.у. ирләр һәм хатын-кызлар авыруларын дәвалауда кулланыла. Ләм процедуралары организмга төрле яклап: тукымалар трофикасына, аксым синтезына, нейрофизик статуска уңай тәэсир итәләр, иммун системасы функциясен стимуллаштыралар. Аларның микроб һәм вирусларга, шешкә каршы торучанлыгы исбатлана.

ТРда Ш.л.нең 8 чыганагы бар, иң зурлары: Тәбәрле-3 (Әгерҗе р-ны), Югары Мочажина

(Лениногорск р-ны). Ләм б-н дәвалау ихтыяҗын Зәңгәр һәм Исемсез (Биектау р-ны) күлләрнең лайлалы ләмнәре, торфлы ләм чыганаклары — Тәбәрле-3, Бәкер (Лениногорск р-ны) һәм Азнакай р-ны сазлыклары канәгатьләндерә. Ш.у.к. *Күкертле-водородлы су чыганаклары һәм шифалы ләмнәр.*

Н.И.Афанасьева.

**ШИФА́Н**, к. *Аю баланы.*

**ШИХМАМЕ́ТОВЛАР**, татар морзалары нәселе. Бихан бәк варислары. 1613–14 елларда Дивәй морза Алакаев Темников өязендәге Акчеево авылында — утар, 1639–41 дә Аеш морза б-н Ураз морза Диваевләр Саранск өязе Дивәй авылында 3 крәстиян хуҗалыгы, шул ук өяздә Туктар, Ураз һәм Килмәш морза Диваевләр утар билиләр. 17 йөз исәп алу кенәгәсендә Туктар «Тохтар мурза Дивеев сын князь Шихмаметев» дип күрсәтелә. 1698 дә Темников, Саранск һәм Сызрань өязләрендә Тимофей морза Богдан улы кенәз Шихмаметов биләмәсендә утар җирләре була. 18–19 йөзләрдә Ш. Пенза губернасының Красная Слобода өязе Агишево, Лобановка, Баишево (Баеш), Акчеево (Күгеш) һәм Саранск өязе Лямбир (Ләмбрә) авылларында, Сембер губернасының Алатыр өязе Красный Яр авылында яшиләр. 19 йөзнең башында Ш. Уфа губернасының Бәләбәй өязе Каргалы, Бүздәк, Иске Биккенә авылларына килеп урнашалар. Краснослободск өязендә яшәгән морза Ш. Пенза губернасы дворян шәҗәрәләре китабының 6 нчы кисәгенә кертелә. Православие динен кабул иткән Ш. 19 йөзгә кадәр кенәз титулын йөртәләр; Сенат бары тик дворян титулын раслый.

*Әд.:* Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

**ШИҺАБЕТДИ́НОВ** Альберт Кашаф улы (12.11.1952, Свердловск өлкәсе Первоуральск ш.), радиоинженер, хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТРның атказ. икътисадчысы (2002). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук инженер булып эшли. 1978 елдан «Нармонка» с-зы директоры урынбасары (Лаеш р-ны). 1983–86 да Казан шәһәре Бауман р-ны азык-төлек сәүдәсе идарәсендә бүлек башлыгы, директор урынбасары. 1986 дан база башлыгы, 1987 дән «Татрыбпром» берләшмәсенең ген. директоры урынбасары. 1991 дән — «Казан» тышкы сәүдә ФҖБ, 1995 тән «ТАИФ» АҖ ген. директоры, бер үк вакытта «Түбәнкаманефтехим», «Казаноргсинтез» АҖләре Директорлар советы рәисе. Ш. җитәкчелегендә ТРда иң эре һәм РФдә иң эреләрнең берсе булган «ТАИФ» холдинг компаниясе оештырыла (аның составына 50 дән артык киң диверсификацияле эшчәнлекле, нәтиҗәле идарә формалы, куәтле җитештерү потенциалына һәм югары дәрәҗәле менеджментка ия бүлендек һәм бәйле пр-тиеләр керә), нефть эшкәртү, нефть химиясе, төзелеш (Болгар ислам академиясе комплексы биналары төзелешен финанслауда катнашу) һ.б. өлкәләрдә күп кенә эре инновацион проектлар гамәлгә ашырыла, мәдәни һәм рухи мирасны яңарту (мәс., Зөядә музей-тыюлык төзү), спортны үстерү (мәс., «Рубин» футбол, «Синтез» ватерпол, «Нефтехимик» хоккей клубларына спонсорлык ярдәме) һ.б. юнәлешләрдә социаль мөһим проектларны гамәлгә ашыру буенча актив эш алып барыла. 2009 дан ТР халык депутаты. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2009). Почёт, ТРның «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» һәм «Дуслык» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШИҺАБИ́ЕВ** Тәлгать Нигъмәтҗан улы (5.3.1939, Арча р-ны Иске Йорт а.), җылылык физикасы белгече, техник фән. д-ры (1998), проф. (2004), ТАССРның, РСФСРның атказ. тәгүчесе (1986, 1989). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1966), Татарстан газ комплексы оешмаларында эшли. 1984 елдан трест идарәчесе, 1995 тән «Востокстройтрансгаз» ген. директоры, бер үк вакытта, 2007 дән, Казан вет. медицинасы академиясенең метрология һәм сыйфат б-н идарә итү каф. мөдире. Хезмәтләре сыек мохитләр кайнау процессының физик нигезләрен өйрәнүгә карый. Ш. сыекчаларның, бинар катнашмаларның үзлекләрен, аларның басым һәм вакуум шартларында кайнау үзенчәлекләрен; җылы бирү механизмына мохитнең составы һәм басым йогынтысын; тигезләнеш шартларын; термокапилляр эффектларны тикшерә. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты. Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы газ сәнәгате хезмәткәре (1999).

Х е з м.: Эндотермические топлива и рабочие тела силовых и энергетических установок. К., 1996 (автордаш); Физические основы процесса кипения жидких сред. К., 2003; Функционально-стоимостной анализ качества продукции К., 2010 (автордаш).

**ШИҺАЗДА́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 9 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сула елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 336 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 72%, татарлар — 27%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, кошчылык. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ильинский, Зур Шиһазда исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, паркет ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.да Илия чиркәве (1801 дә төзелә), земство мәктәбе (1884 тә ачыла), җил тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 713,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Колай волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 159 ир-ат; 1859 да — 375, 1897 дә — 461, 1908 дә — 535, 1920 дә — 518, 1926 да — 595, 1949 да — 284, 1958 дә — 253, 1970 тә — 312, 1979 да — 236, 1989 да — 159, 2002 дә — 342 кеше.

**ШИҺА́ПОВ** Айрат Баһаветдин улы (5.1.1938, Теләче р-ны Сауыш а.), җылылык энергетикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1995), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2008). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1965), шунда ук эшли. 1996 дан Казан энергетика ин-тының җылылык электр станцияләре каф. профессоры. Хезмәтләре радиацион җылылык алмашуга, радиацион көчерүнең кире мәсьәләләренә, энергетик каты ягулыклар януына, стационар газ турбиналы җайланмалардагы эш процессларына карый. Ш. җылылык алмашу мәсьәләләрен хәл итү өчен нурланыш энергиясен көчерүнең хисаплау алымнарын (реаль шартларга максималь якынлашып, җайланманың геометрик үзенчәлекләрен, мохит параметрлары таралышын, газсыман фаза үзлекләрен һ.б.ны исәпкә алып) эшли. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2004).

Х е з м.: Перенос энергии излучения в энергетических установках. К., 2003; Теоретические основы нефелометрии дисперсных сред. К., 2003 (автордаш); Стационарные газотурбинные установки тепловых электрических станций. К., 2009.

**ШИҺА́ПОВ** Мансур Әхмәт улы (1.5.1940, Балык Бистәсе р-ны Яншык а.), шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992), ТРның атказ. артисты (2012). Казан театр уч-щесен (1961), Казан ун-тын (1981) тәмамлый. 1961 елдан Татар филармониясендә сөйләм жанры артисты, 1969 дан ТАССР Язучылар берлегенең пропаганда бюросы директоры урынбасары, 1972 дән Татар дәүләт акад. театрында баш администраторы, 1974 тән Казан курчак театры директоры, 1979 дан Татар драма һәм комедия театры директоры, 1984 тән ТАССР Язучылар берлеге рәисе урынбасары, 1996 дан Зур концерт залы директоры, 2009 дан Заманча музыка үзәге директоры, 2012 дән Казан театр уч-щесендә укыта. «Әйләнеп кайтыгыз» (1985), «Туй күлмәге» (1990) шигырь җыентыклары, «Җырлыйсы җырларым бар әле» (2005), «Язгы ташкын булып» (2010) шигырь һәм публицистика җыентыклары авторы. Иҗатының төп темасы — туган илгә, туган йортка мәхәббәт. Ш. поэзиясенә халык поэтикасы, моң, гадилек һәм әчкерсезлек хас. Ш. шигырьләренә композиторлар С.Ибраһимов, Р.Яхин, С.Садыйкова, Р.Хәсәнов көйләр иҗат итәләр. «Абага чәчәге» (Г.Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» әсәре буенча; Казан курчак театрында куела, 1977), «Кара йөзләр» (М.Гафуриның шул ук исемдәге романы буенча; Казан курчак театрында куела, 1980), «Кошның да үз оясы була» (Г.Ахуновның «Хәзинә» романы буенча; Татар драма һәм комедия театрында куела, 1982) инсценировкалары авторы.

*Әд.:* Хәмидуллин Л. Күп кырлы иҗат иясе // Казан утлары. 2005. №5.

**ШИҺА́ПОВ** Рәшит Әхмәт улы (6.1.1938, Балык Бистәсе р-ны Яншык а. — 21.8.2003, шунда ук), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1963). 1961 елдан ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тының Казан, 1963 тән Лениногорск студияләре режиссёры. 1993–98 дә «Заман сулышы» (Лениногорск ш.) г-тасында сәнәгать бүлеге мөдире, бер үк вакытта, 1989–2003 тә, Лени-

ногорск халык театры режиссёры. «Хисләр давылы» (Лениногорск, 1992), «Җырларымнан мине эзләгез» (Лениногорск, 1993), «Сыкрау» (Лениногорск, 1997), «Заман белән бәхәс» (1997), «Юлларда язмышлар» (2000), «Тормыш кыры» (2001), «Ишетәсеңме?» (2002), «Мин яшәдем» (2008) җыентыклары авторы. Ш. иҗатының төп темасы — авыл тормышы, пейзаж һәм мәхәббәт лирикасы; аның поэзиясенә фәлсәфи уйланулар һәм җылы юмор хас. 2003 тә Лениногорск халык театрына Ш. исеме бирелә.

**ШИҺА́ПОВ** Фәрит Зөфәр улы (5.8.1951, Сарман р-ны Карамалы а.), трубада уйнаучы, педагог, ТРның халык артисты (1995). 1975 елда Казан консерваториясен (А.Величко классы) тәмамлый. 1971–78 һәм 1981–95 тә Татар опера һәм балет театры оркестрының трубачылар төркеме артисты һәм концертмейстеры (1973 тән), 1996–98 дә — Казан консерваториясендә камера ансамбле классы, 2007 дән труба һәм тынлы музыка уен кораллары ансамбле классы укытучысы. Й.Гайдн, И.Гуммель, А.Арутюнян һ.б.ның әсәрләреннән торган репертуар б-н концертларда чыгыш ясый.

**ШИ́ШКИН** Александр Александрович (3.7.1909, Казан — 1993, шунда ук), тарихчы, тарих фән. д-ры (1974), проф. (1975). Казан финанс-икътисад ин-тын (1933), Казан дәүләт ун-тын (1937) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1937 елдан Яшел Үзән шәһәрендә эшли. 1946 да ВКП(б) Татарстан өлкә ком-тының мәдәният һәм мәгариф секторы инструкторы, 1947 дән Казан юридик ин-ты укытучысы. 1952–55, 1957–89 да Казан ун-тында. Хезмәтләре ярлылар ком-тлары, дини секталар тарихы мәсьәләләренә карый. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Комитеты деревенской бедноты. К., 1961; Октябрь в деревне. К., 1967 (автордаш); Сущность и критическая оценка обновленческого раскола русской православной церкви. К., 1970.

*Əд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр.словарь. К., 2002. Т. 3.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ШИ́ШКИН** Анатолий Всеволодович (2.4.1928, Иваново өлкәсенең Лух р-ны Панинский а. — 4.2.2010, Казан), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998), геол.-минерал. фән. канд. (1956), ТРның атказ. геологы (1996), РФнең мактаулы җир асты байлыклары разведчигы (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1951). 1955 елдан ЦНИИгеолнерудта, тау-техник чимал геологиясе бүлеге мөдире (1995 тән), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2006 дан). Хезмәтләре файдалы казылмалар чыганаклары геологиясенә карый. Ш. доломитлардан сәнәгать күләмендә магнезия беркеткечләрен җитештерү мөмкинлеген, ТРда гипс һәм карбонат токымнарының чимал базасы үсешенең киләчәген нигезли. *Мәрмәр ониксы* чыганагын беренче булып ачучыларның берсе. ТР Дәүләт бүләге ТРның утырма токымнар катламнарында яңа һәм гадәти булмаган файдалы казылмаларны ачуы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШИ́ШКИН** Владислав Иванович (27.6.1940, Чуаш АССРның Цивильск р-ны Иваново а.), библиограф, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук Фәнни китапханәдә эшли (1964 елдан): өлкән библиограф, 1968 дән баш библиограф, 1973–92 дә фәнни-библиографик бүлек мөдире, 1992 дән кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире, 2003 тән баш библиограф, 2008 дән фәнни-библиографик бүлек мөдире. Казанның рев-циягә кадәрге рус телендәге вакытлы матбугаты библиографик күрсәткечен төзи (1985). Казан ун-тының Фәнни китапханәсе буенча (1986, 1997), кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең кулъязмалар фонды юл күрсәткечен (1999), Казан ун-тының вакытлы басмалары, Казанның рев-циягә кадәрге газета һәм журналлары эчтәлеге күрсәткечләрен, «Казан университеты профессорлары һәм укытучыларының биобиблиографик сүзлеге, 1905–1917» («Биобиблиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета, 1905–1917», 1986), «Казан университетының тарих факультеты профессорлары» («Профессора исторического факультета Казанского университета», 1999), «Казан университеты. 1804–2004» («Казанский университет. 1804–2004», Т. 1–2, 2002–04) һ.б. сүзлекләр төзүдә катнаша. «Казан университеты тарихы очерклары» («Очерки истории Казанского университета», 2002) китабы авторлары һәм мөхәррирләренең берсе.

Х е з м.: Казанские частные библиотеки для чтения 30–60-х годов XIX в. // Библиотека Казанского университета: фонды, раритеты, история... К., 1989 (автордаш); Организация работы над научно-вспомогательными библиографическими указателями // Библиографическая работа вузовских библиотек. К., 1989.

**ШИ́ШКИН** Иван Васильевич (30.5.1792, Вятка губ. Алабуга ш. — 1.11.1872, шунда ук), тарихчы, археолог, эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе. Рәссам И.И.*Шишкинның* атасы. 1823–26 елларда Алабуга шәһәр магистраты бургомистры, 1832–35, 1844–47 дә Алабуга шәһәр думасы шәһәр башлыгы. Шәһәр үсешенә, ш.и. тарихи истәлекләрне реставрацияләүгә, суүткәргеч төзүгә (1833) зур өлеш кертә; туган як тарихын өйрәнә. 1858 дә П.В.Алабин б-н Ананьино каберлегендә казу эшләре алып бара. Бу эшчәнлек Кама буенда элгәреге тимер гасырны тикшерү процессын башлап җибәрүгә һәм яңа археол. культурага (к. *Ананьино культурасы*) нигез салырга этәргеч бирә. 1867 дә Мәскәү ун-ты профессоры К.И.Невоструев җитәкчелегендә «*Шайтан каласы*» манарасын реставрацияли. Мәскәү тарих-археол. җәмгыяте мөхбир әгъзасы (1872).

Х е з м.: История города Елабуги. М., 1871.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ШИ́ШКИН** Иван Иванович (13.1.1832, Вятка губ. Алабуга ш. — 8.3. 1898, С.-Петербург), нәкышьче, рәссам, гравёр, сәнгать академигы (1865), проф. (1873), СА хакыйкый әгъзасы (1893). САнең пейзаж остаханәсе җитәкчесе (1894–95). Күчмә сәнгать күргәзмәләре ширкәтен гамәлгә куючы һәм аның актив катнашучысы (1870), Сәнгатькә ярдәм итү җәмгыяте



Ф.З.Шиһапов.



И.И.Шишкин.

(1869), Рус акварфортчылар җәмгыяте (1871) әгъзасы. Илдә 19 йөзнең 2 нче яртысы реалистик пейзажына нигез салучыларның берсе. Тарихчы, эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе И.В.*Шишкин* гаиләсендә туа. 1844–48 елларда Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә укый. 4 сыйныфны тәмамлаганнан соң, автобиографиясендә язганча, «тар формалистикалы гимназия»дән азат булып, укудан туктый. 1848–52 дә Алабугада яши, үзлегеннән сәнгать буенча белемен арттыру б-н шөгыльләнә. 1850 дә Мәскәү Строганов уч-щесен тәмамлаган И.А.Осокин (Алабуга собор чиркәвенең иконастасын бизәргә чакырыла) б-н таныша, ул булачак рәссамга уңай йогынты ясый. Ш.ның этисе улының рәссам булу теләген хуплый; аңарда тарихка карата кызыксыну уята, аны борынгы Болгарда археол. казу эшләре алып барган Мәскәү профессоры К.И.Невоструевка ярдәмгә җәлеп итә. 1852–56 да Ш. Мәскәү сынлы сәнгать һәм скульптура уч-щесендә А.Н.Мокрицкий җитәкчелегендә, 1856–60 та САдә С.М.Воробьёвның пейзаж сәнгате классында укый. 1860 та Ш. 1 нче дәрәҗәле рәссам исеме һәм 3 елга чит илгә пенсионер булып бару хокукы ала. 1861 нең маеннан октябренә кадәр Алабугада яши, шәһәр тирәсендә һәм Казан губернасының Спас өязендә этюдлар яза: «Ананьино каберлеге», «Кырдагы җил тегермәне», «Үзәндәге юл», «Шәфәкъ вакытында сазлыклы урын», «Куыш», «Болгар хәрабәләре (Ак пулат)», «Болгардагы хан төрбәсе хәрабәләре һәм Кече манара» (барысы да ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда). 1862 дә чит илгә (Германия, Швейцария) бара. 1865 тә Россиягә әйләнеп кайтканнан соң, нигездә, Петербургта яши. 1858 дә литография, 1870 еллар башында офорт б-н кызыксына, кабарынкы офорт техникасын уйлап таба. Рәсемнәр сериясе (каләм, күмер, акбур, 1860–70) авторы. Ш. Казанның мәдәни тормышында тирән эз калдыра, күп рәссамнар, мәдәният әһелләре, эшмәкәрләр б-н тыгыз элемтәдә була. Коллекционер А.Ф.Лихачёв заказы буенча Ш. әсәрләренең Казандагы тупланмасына башлангыч булган «Швейцария пейзажы»ның вариантын эшли (1866). Картиналары Казанда яшәүче О.С.Александрова-Гейнс, Л.В.Кекин, П.А.Радимов, Г.М.Залкинд, П.К.Ушков һ.б.ның шәхси тупланмаларында җыйнала. 1897 дә Ш. Казан сынлы сәнгать мәктәбенә рәсемнәрен, офортларын һәм 6 этюдын бүләк итеп бирә. 1879 да Иделдә Самарага кадәр сәяхәт итә. Алабугага кайткалап йөри (1865, 1868, 1877, 1884), шәһәр тирәсендә натурадан этюдлар

ясый. «Алабуга янындагы Кызыл Тау» (1852), «Наратлык. Вятка губернасында мачта урманы» (1872), «Бай үзән. Камадагы ак чыршы урманы» (1877), «Арыш басуы» (1878), «Кама» (1882), «Урман киңлекләре» (1884), «Алабуга янындагы Изге чишмә» (1886), «Алабуга янында Кама елгасы» (1895), «Алабуга янында Афанас кораб урманы» (1898) һ.б. картиналарында Кама буе табигатен чагылдыра.

Бөтендөнья Париж һәм Вена күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре РФ һәм БДБ илләренең иң эре сынлы сәнгать музейларында куелган, төп тупланмасы Третьяков галереясында, Рус музеенда саклана. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда Ш. әсәрләренең әһәмият ягыннан өченче урында торган, 40 нәкышь картинасын, 25 рәсемне, 400 ләп гравюраны эченә алган тупланмасы бар. 1960 та Алабугада Шишкиннар йортындагы төбәкне өйрәнү музее Шишкин И.И. музей-йорты итеп үзгәртелә. Музей терр-ясендә рәссамга һәйкәл куела (1991, скульп. Ю.Г.Орехов, архитекторлары С.Н.Купреянов, А.В.Степанов). И.И.Шишкинның портретлары И.Е.Репин (1877), И.Н.Крамской, В.П.Верещагин (1861), И.А.Осокин (1850) тарафыннан языла.

*Әд.:* К о р н и л о в П.Е. На родине Шишкина. К., 1929; Д у л ь с к и й П.М. Иван Иванович Шишкин. 1832–1898. К., 1953; Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан. Русское искусство XVII — начала XX века. Живопись: Каталог. К., 2005; К л ю ч е в с к а я Е.П. Азы рисовального искусства и боязнь «сделаться чиновником»: Казань и казанцы в творческой судьбе И.И.Шишкина // Казань. 2009. № 4.

*Е.П.Ключевская, И.Ф.Лобашёва.*

**ШИ́ШКИН И.И. МУЗЕ́Й-ЙОРТЫ́**, Алабуга шәһәрендә, мемориаль музей. 1962 елда РСФСР Мәдәният министрлыгының 1960 ел 23 август боерыгы нигезендә ТАССР Дәүләт сынлы сәнгать музее ф-лы буларак оештырыла, 2004 тән Алабуга тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгы составына керә; рәссамның балачак һәм яшьлек еллары узган Шишкиннар гаиләсе йортында урнашкан. 1937 гә кадәр ике катлы йорт (1836; архит-ра истәлеге) туганнарының милке була, 1960 ка кадәр анда төрле учреждениеләр, ш.и. И.И.*Шишкинга* багышланган экспозицияле төбәк тарихы музее урнаша (1946 дан). Мемориаль музей оештырылганнан соң, экспозицияне (биография бүлеге һәм картиналар галереясы) беренче катта урнаштыралар. 1971–75 тә Ш.м.-й. реконструкцияләнә: йорт тулысынча музейга тапшырыла, мемориаль комплекс булдырыла, утарның терр-ясе киңәйтелә. Музей комплексының фәнни концепциясе эшләнә (Г.А.Могильникова, В.К.Чернышова, С.В.Бобкова, баш рәссам В.В.Бочаров), 19 йөздәге сәүдәгәр көнкүреше күренеше торгызыла. Экспозициянең мәйданы 344 $м^2$, фондларында 461 саклау берәмлеге исәпләнә. Экспонатлар 9 бүлмәдә: беренче катта — зур һәм кечкенә кунак бүлмәләрендә, рәссамның әтисе бүлмәсендә, ш. у. аш һәм буфет бүлмәләрендә, икенче катта — остаханәдә һәм рәссам бүлмәсендә (бүлмәнең эчке күренеше И.И.Шишкинның 1850 елларда ясалган «Алабугадагы бүлмә күренеше» рәсеме буенча торгызыла), ш.у. И.И.Шишкинның нәкышь һәм графика әсәрләренең төп нөсхәләре урын алган картиналар галереясы урнашкан ике залда куелган. Коллекцияләрне мемориаль предметлар б-н тулыландыруга О.П.Гвоздева (рәссамның бертуганының оныгы), М.М.Рыбальская (олы кызының оныгы) булышлык итәләр. Кыйммәтле экспонатлар арасында — И.И.Шишкинның нәкышь (10) һәм графика (50 дән артык) әсәрләренең төп нөсхәләре, дусларының, шәкертләренең һәм замандашларының, ш.и. В.П.Верещагин (7 саклау берәмлеге) картиналары, рәссамның өендә кулланылган яисә рәссамның үзенең мемориаль предметлары (80 якын саклау берәмлеге).

Музей каршында шәһәр зыялыларының «Яр буендагы йортта» иҗат клубы эшли (2004 тән). Ел саен респ-ка яшь рәссамнар конкурсы уздырыла. Ш.м.-й. фәнни хезмәткәрләре Шишкиннар нәселенең тарихын өйрәнәләр, алар тарафыннан «Шишкиннарның нәсел шәҗәрәсе» («Генеалогическое древо рода Шишкиных») төзелә, «Шишкиннар нәселенең өч йөз еллык шәҗәрәсе» («Трёхсотлетнее древо рода Шишкиных», төзүчесе Н.И.Курылёва, Алабуга, 2008) китабы нәшер











И.И.Ш и ш к и н. 1. «Наратлык. Вятка губернасында мачта урманы». 1872. Рус музее; 2. «Алабуга янында Кама елгасы». 1895. А.М.Горький әдәби-мемориаль музее. Казан. 3. «Урман юлы». 1880. Рус музее; 4. «Болгардагы хан төрбәсе хәрабәләре һәм Кече манара». Картон. Майлы буяу. 1861. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. «Учак янында». Кәгазь. Офорт. 1873.







1. Алабуга шәһәрендә И.И.Шишкин музей-йорты; 2. Рәссамның остаханәсе; 3. Зур кунак бүлмәсе.

ителә. Ш.м.-й. директорлары: Е.С.Минкина (1961–62), И.П.Сливчикова (1962–64), С.В.Бобкова (1964–65; 1973–94), Ф.К.Йосыпова (1965–70), Г.Н.Воробьёв (1970–72), М.М.Башкирова (1994–2005), Л.Л.Башкирова (2005 тән).

*Әд.:* Дом-музей И.И.Шишкина в Елабуге. К., 2003; Российская музейная энциклопедия. М., 2001. Т. 2.

**ШКА́НОВ** Игорь Николаевич (8.5.1930, Казан — 7.9.2005, шунда ук), очу аппаратлары ныклыгы өлкәсе галиме, техник фән. канд. (1965), проф. (1990), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1994). 1953 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техника ун-ты) тәмамлый, шунда ук, материаллар белеме һәм технологиясе кафедрасында эшли, каф. мөдире (1979–89), каф. профессоры (1991–2001). Хезмәтләре очу аппаратларын һәм моторларын җитештерүнең металлургия циклы процессларын технол. яктан оптимальләштерүгә карый. Ш. конструктив материалларны катлаулы киеренке хәлдә сынау алымнарын һәм чараларын эшли; очу аппаратлары һәм моторлары ресурсын арттыру максатында аларны җитештерүнең технологиясен камилләштерү буенча тикшеренүләр алып бара. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХның көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экспериментальная проверка критериев усталостной прочности при двухосном растяжении // Проблемы прочности. 1970. № 2; Методы контроля и прогнозирования неразрушения материалов и элементов конструкций ДЛА. К., 1990; Прогнозирование скорости развития трещин алюминиевых сплавов и их соединений при двухосном малоцикловом нагружении // Проблемы машиностроения и автоматизации. 1991. № 5 (автордаш).

**«ШКУ́РА, КО́ЖА И О́БУВЬ»** («Тире, күн һәм аяк киеме»), журнал. 1910 елның 11 февраленнән 1911 нең 10 февраленә кадәр Казанда, 1911 нең февраленнән 1915 кә кадәр Петроградта 2 атнага 1 тапкыр рус телендә нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире — техник-инженер, Алафузовларның күн заводы директоры А.А.Завадский. Редакция үзенең максаты итеп Россия күнчеләренә заманча җитештерүне оештыруда ярдәм итүне саный. Журнал Россиянең күн сәнәгате хәле, илдә һәм чит илдә чималга бәяләр, материаллар, күн эше яңалыклары б-н таныштыра. Россия күн заводчылары съездының күн мәктәпләре: башкалада — югары, урыннарда урта һәм түбән мәктәпләр оештыру, ш.у. чит ил чималы һәм материалларын арадашчыларсыз бергәләшеп алу турындагы карарларын яклый. Чит ил чыганакларындагы тәрҗемә язмаларга күп урын бирелә.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ШКУРИ́ХИНА** Дарья Валерьевна (3.10.1990, Казан), спортчы (нәфис гимнастика), Россиянең атказ. спорт остасы (2007). 2004 елдан Түбән Новгород шәһәрендә яши. Түбән Новгород ун-тын тәмамлый (2013). Спорт б-н 1995 тә Олимпия резервындагы «Приволжанка» махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (Казан) шөгыльләнә башлый. Тренерлары: М.Н.Борзенкова, Л.И.Васина (1995–2003), И.А.Винер, Н.Б.Тишина, Т.В.Сергаева, В.А.Иваницкая, Я.В.Яринцева (2004–08). 2002–04 тә яшьләр җыелма командасы, 2005–08 дә Россия милли җыелма командасы составында. «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте (Түбән Новгород) һәм Мәскәү шәһәре физкультура-спорт берләшмәсе өчен чыгыш ясый. Европа чемпионатларында (2006, 2008) төркемле күнегүләрдә, Олимпия уеннарында (2008, күптөр ярыш һәм аерым предметлар б-н күнегүләр) җиңүче. Дуслык ордены б-н бүләкләнә (2009).

**ШЛАМА́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кондырча елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 37,8 *км*, ТР чикләрендә — 8 *км*. Бассейнының мәйданы 250 *км²*. Идел аръягы түбәнлегеннән ага. Елганың башы һәм югары агымы Самара өлкәсендә, түбән агымы ТР-ның Нурлат р-ны терр-ясендә, тамагы Яңа Иглай авылыннан 2 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Ш.ның Самара терр-ясеннән агучы 6 кушылдыгы бар. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Озак вакыт яңгырлар булмаганда, елганың кайбер урыннары кибә, су фәкать елга юлының тирәнәйгән урыннарында гына сакланып кала. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада 4 буа корылган. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШЛЕЙМО́ВИЧ** Лев Моисеевич (1897, Чернигов губ., хәзер Брянск өлкәсенең Стародуб ш. — 24.10.1953, Казан), флейтачы, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939). 1916 елда Петроград консерваториясен (Ф.В.Степанов, В.Н.Цыбин классы) тәмамлый. 1918 елдан — Казанда опера һәм симф. оркестрларда, ш. и. 1942–45 тә Татар опера һәм балет театры оркестрында эшли. Бер үк вакытта, 1921–22 дә, Шәрекъ консерваториясендә, 1922 дән Казан музыка уч-щесендә, 1945 тән Казан консерваториясендә укыта. Флейта, гобой, фагот класслары алып бара, 200 дән артык укучы тәрбияли, алар арасында А.Геронтьев, Н.Зайдель, Р.Таймасов һ.б. бар. Методик күрсәтмәләр, тынлы агач музыка уен кораллары өчен эшкәртелгән күчермәләр һәм әсәрләр авторы.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ШЛЯ́ПНИКОВ** Михаил Сергеевич (23.9.1923, Чистай кантоны, хәзер Алексеев р-ны Биләр а. — 30.11.2001, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (7.7.1944, 13.3.1945 — 1951нең 20 декабрендә 1 нче дәрәҗә Дан орденына үзгәртеп бүләкләнә, 11.6.1945), гв. старшинасы. Туган җирендә комбайнчы булып эшли. 1942 елның апреленнән Кызыл Армиядә. 1942 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 79 нчы гв. укчы полкының танкка каршы мылтык төзәүчесе, 186 нчы гв. артиллерия полкының (11 нче гв. армиясенең 26 нчы гв. укчы дивизиясе) дивизион идарәсе разведчик-күзәтүчесе. 2 нче Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Брянск (1943), Белоруссия (1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 28 июнендә Толочин шәһәреннән (Белоруссия ССР) 16 *км* көньяк-көнбатыштарак барган сугышларда дошманның контрһөҗүмен кире кайтарганда 2 танкны юк итә; 1945 нең 31 гыйнварында Кёнигсберг (хәзер Калининград) шәһәреннән көньяк-көнбатыштарак Интервальде торак пункты янында дошман оборонасын өзгәндә дошманның 105 *мм* лы туплар батареясының ут позициясен күзәтә һәм аның мәгълүматлары нәтиҗәсендә батарея сафтан чыгарыла, шәхсән үзе 10 лап немец солдатын юк итә; 1945 нең 6 апрелендә Кёнигсберг өчен барган сугышларда 3 пулемёт ноктасы һәм 2 тупның координатларын билгели, яралана, әмма дошманның ут нокталарын ачыклавын, күзәтүен дәвам итә. Демобилизациядән соң (1946), ту-



М.С.Шляпников.



А.Т.Шмарёв.

ган җиренә кайта. Биләр элемтә бүлеге берләшмәсендә участок башлыгы булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Биләр мәктәбе бинасында Ш. истәлегенә багышлап мемориаль такта куелган, Хәрби-патриотик «Юнармеец» клубына аның исеме бирелә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ШМАРЁВ** Алексей Тихонович (18.1.1913, Терек өлкәсенең Нальчик бистәсе, хәзер Кабардин-Балкар Респ-касы — 2.6.1993, Мәскәү), геолог-нефтьче, хакимият-хуҗалык эшлеклесе, техник фән. д-ры (1966), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1983), СССРның мактаулы нефтьчесе (1987). Россия нефть һәм газ сәнәгатен оештыручыларның берсе. Грозный нефть ин-тын тәмамлый (1938). 1938–50 елларда Башкортстанның нефть оешмаларында эшли. 1950–56 да «Татнефть» берләшмәсе башлыгы. 1956–57 дә СССР МС каршында Газ сәнәгате баш идарәсе башлыгы. 1957–60 та ТАССР ХХС рәисе, 1960–63 тә РСФСР ХХС рәисенең беренче урынбасары, 1963–65 тә Урта Идел буе ХХС рәисе. 1965–77 дә РСФСР геология министрының беренче урынбасары. 1977 дән Мәскәүдә фәнни-тикшеренү учреждениеләрендә, ш.и. 1989 дан Бөтенроссия шельфны үзләштерү мәсьәләләре ин-тында. Татарстанда нефть сәнагате үсешенә зур өлеш кертә. Ш. җитәкчелегендә Ромашкино нефть чыганагы эшкәртелә башлый, «Татнефть» берләшмәсенең җитештерү һәм социаль структуралары булдырыла, тизләтелгән бораулау режимы һәм бораулау корылмаларының индустриаль ысулы киң тарала, нефть чыгаруның яңа — контур эченә су кудыру алымы эшләнә (1950 еллар ахырына берләшмәдә 40 тан артык пр-тие һәм оешма эшли; 1956 да илдә нефть чыгару буенча беренче урынга чыга). Шулай ук Ш. Көнбатыш Себер һәм Россиянең башка төбәкләрендә нефть, газ чыганакларын үзләштерүгә, бораулау өлкәсендә күп кенә әйдәп баручы, ш.и. Арктикага кагылышлы проектлар буенча оештыру эшләренә зур өлеш кертә. СССРда нефть һәм газ сәнәгате үсешенә багышланган язмалар авторы. 1951–55 тә РСФСР, 1955–62 дә ТАССР ЮСлары депутаты. СССР Дәүләт бүләге (1950), Ленин бүләге (1962) лауреаты. Ике Ленин ордены, биш Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Бөгелмә шәһәрендә Ш.ка һәйкәл куела (2004).

Хезм.: Татария — крупнейший нефтедобывающий район страны // Нефт. хоз-во. 1959. № 1; Развитие буровых работ в Башкирии и Татарии. М., 1966.

*Әд.:* Салманов Ф.К. К 85-летию со дня рождения Алексея Тихоновича Шмарёва // Геология нефти и газа. 1998. № 1. *В.М.Смелков.*

**ШМЕЛЁВ** Фёдор Иванович (15.11.1837, Тверь губ., Гора Новоторжский өязе Михайлова Гора а. — 24.4.1905, С.-Петербург), юрист, яшерен советник (1891), сенатор (1895). Руханилар катлавыннан. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1862). 1862–66 елларда Сенатның 8 нче департаментында хезмәт итә (С.-Петербург). 1966–70 тә Тула округ мәхкәмәсе әгъзасы, 1970–74 тә Самара округ мәхкәмәсе рәисе урынбасары. 1874–79 да Вятка җинаять һәм гражданлык эшләре мәхкәмә палатасының гражданлык бүлеге рәисе. 1879–80 дә Одесса, 1880–86 да Киев мәхкәмә палаталары гражданлык эшләре департаментлары рәисе. 1886–95 тә Казан мәхкәмә палатасы өлкән рәисе. 1895 тән Сенатның гражданнар кассация департаментында.

*Әд.:* Альманах современных русских государственных деятелей. СПб., 1897; Мурзанов Н.А. Словарь русских сенаторов. 1711–1917 гг.: Материалы для биографий. СПб., 2011.

*Е.Б.Долгов.*

**ШМИДТ** Александр Кириллович (1783 — 31.3.1843, Түбән Новгород ш.), архитектор. Вак чиновник улы. Петербург САн тәмамлаганнан соң (1806), Курск губернасына архитектор итеп җибәрелә, 1809 елдан — Казан ун-ты архитекторы, 1810 нан — Казан губернасы архитекторы. 1834 тән — Түбән Новгород губернасы архитекторы. 1812–15 тә күп кенә хәзергәчә сакланган һәм юкка чыккан корылмалар, ш.и. Болгар шәһәрлеге истәлекләренең, Казандагы Петропавел соборының беренчел үлчәм сызымнарын эшли. 1818– 23 тә Казанны яулаганда һәлак булган *Рус гаскәрләре һәйкәл-төрбәсен* төзүгә җитәкчелек итә (башка мәгълүматлар буенча арх. М.Е.Емельянов), бинаның проект авторы арх. Н.Ф.Алфёров тәкъдим иткән кирпеч йөзлеген ак ташка алмаштыра. Ш. проектлары буенча Казанда классицизм стилендә күп кенә торак йорт, ш.и. гражданнар губернаторы йорты (1820 еллар), Гордеев (1833), Свешников (1834) йортлары төзелә; Казан магистраты бинасы (1815), Иске таш мәчет (1830) һ.б. төзекләндерелә.

*Әд.:* Муртазина Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999. *Л.М.Мортазина.*



А.К.Шмидт. Гражданнар губернаторы йорты. Казан. В.Турин офорты. (Хәзер Кремль урамы, 12).

**ШМИДТ** Лидия Семёновна (5.12.1908, Киев губ., Киев өязе Демиевка а. — 28.12.1973, Казан), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1954). Киев театр техникумын тәмамлый (1927). Сәхнә эшчәнлеген Украина күчмә агиттеатрларында («Шахтёрка Донбасса», «Культфронт») башлап җибәрә. 1931–38 елларда — Томск, Сталинск (хәзер Новокузнецк), Новосибирск («Красный факел» театры) шәһәрләрендәге театрларда, 1938–46 да Воронеж театрларында эшли; Бөек Ватан сугышы елларында Воронеж өлкә драма театры б-н бергә Копейск шәһәрендә эвакуациядә була. 1946 дан Казан Зур драма театрында. Аның сәхнәсендә башкарган Софья («Зыковлар», М.Горький), Катя («Михнәтле заман», А.Н.Толстой романы буенча), Лидия Чебоксарова, Кручинина («Котырган акчалар», «Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Верочка («Текә яр», И.А.Гончаров романы буенча), Анна («Анна Каренина», Л.Н.Толстой романы буенча) кебек беренче рольләре Ш.ны труппаның әйдәп баручы актрисалары сафына чыгара. Актриса һәр ролендә хатын-кыз абруен, аның бәхеткә лаек булу хокукын, хисләрен күрсәтә алу ирееген яклый һәм раслый. Василиса («Тормыш төбендә», М.Горький), Глафира, Кабаниха («Бүреләр һәм сарыклар», «Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Анна Григорьевна («Үле җаннар», Н.В.Гоголь), Вазифа («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт), Диана Михайловна («Фамилияләрне атамый гына», В.П.Минко) кебек үткен характерлы образлар иҗат итеп, Ш. аларның социаль асылларын, әхлакый дөньяларын оста ача. Маша, Раневская («Өч сеңел», «Чия бакчасы», А.П.Чехов), Мария Александровна Ульянова («Гаилә», И.Ф.Попов, «Давылга таба», Р.Ишморат) рольләре Ш. башкаруында тирән эчтәлекле булулары, психол. төгәллек б-н гәүдәләнүләре ягыннан, тышкы рәсемнең гүзәллеге һәм нәзакәтлеле-



Л.С.Шмидт.



Л.С.Шмидт Анна ролендә («Анна Каренина», Л.Н.Толстой романы буенча).

ге б-н аерылып тора. Ш. — нәфис сүз остасы да, еш кына концертларда, тамашачылар б-н оештырылган иҗат кичәләрендә чыгышлар ясый, Казан ун-тында студентларның нәфис сүз түгәрәге б-н җитәкчелек итә.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ШМИДТ** Отто Юльевич (18.9.1881, Могилёв ш. — 7.9.1956, Мәскәү), галим-энциклопедист (математик, геофизик, астроном; фән тарихчысы), дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, СССР ФА (1935; 1993 елдан мөхбир әгъза) һәм Украина ССР ФА академигы (1934). Сов. Союзы Герое (1937). Киев ун-тын тәмамлаганнан соң (1913), шунда ук укыта. 1917 дән Петроградта, 1918 дән Мәскәүдә: СССР Азык-төлек, Икътисад халык комис-тлары; РСФСР Мәгариф халык комис-ты коллегияләре әгъзасы; Госиздат директоры (1922–24), Зур совет энциклопедиясенең 1 нче басмасының баш мөхәррире (1924–42). Фән һәм мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәте б-н җитәкчелектә күренекле урын били. Арктиканы үзләштерүне оештыручыларның берсе. 1930–32 дә Арктика ин-ты директоры, 1932–39 да Баш Төньяк диңгез юлы (Главсевморпуть) башлыгы. «Седов» (1929, 1930) һәм «Сибиряков» (1932) бозваткычлы пароходларында оештырылган поляр экспедицияләр җитәкчесе. «Сибиряков»та Төньяк диңгез юлы беренче тапкыр бер навигация вакытында үтелә. 1933–34 тә атаклы «Челюскин» пароходында (йөзүче боз кисәкләре арасында калып кысыла) Төньяк диңгез юлы буйлап оештырылган экспедициягә җитәкчелек итә. 100 дән артык кеше соңыннан «Шмидт лагеры» дигән исем алган боз кисәгендә кала. 1937 нең маенда йөзүче «Төньяк полюс» («СП-1») станциясен оештыру буенча һава экспедициясен җитәкли. СССР ФАнең беренче вице-президенты (1932–42). Мәскәү ун-ты профессоры (1922–56), Мәскәү алгебра мәктәбенә нигез салучы. СССР ФАнең Теоретик геофизика ин-тын оештыручы һәм беренче директоры (1937–49). 1951 дән «Природа» ж-лы директоры. Кояш системасы җисемнәренең газ-тузан болыты конденсациясе нәтиҗәсендә барлыкка килүе турындагы космогоник гипотеза («Шмидт гипотезасы») авторы. 1934–37 дә СССР ҮБК әгъзасы. 1937–46 да ТАССРның Казан сайлау округыннан Милләтләр советында СССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышы елларында Казанда яши, Мәскәү һәм Ленинградтан эвакуацияләнгән акад. учреждениеләрен, фәнни хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларын урнаштыруны оештыручыларның берсе; оборона максатларындагы эшләр буенча СССР ФА һәм Татарстан ВКП(б) өлкә ком-ты фәнни-техник комиссиясен җитәкли. 1942 нең ноябрендә Казан ун-тында «Совет геофизикасына 25 ел» һәм декабрендә Казан шәһәр советының тантаналы утырышында «СССР Конституциясенең биш еллыгы» темасына докладлар ясый. Өч Ленин ордены, өч Кызыл Йолдыз, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә. СССР ФАнең Җир физикасы ин-ты, Карск диңгезендәге утрау, Чукотка диңгезенең көнбатыш өлешендәге борын, Магадан өлкәсендәге район, Яңа Себер утрауларындагы тау тезмәсе, Сахалиндагы ярымутрау, Антарктида боз калканы астында тигезлек; 2108 нче кече планета; Казандагы урам Ш. исеме б-н атала. Ш. исеме Ай картасына кертелә. СССР ФАдә О.Ю.Шмидт исемендәге бүләк булдырыла.



О.Ю.Шмидт.



С.О.Шмидт.



В.Б.Шнепп.

Х е з м.: Избранные труды: Математика. М., 1959; Избранные труды: Географические работы. М., 1960; Избранные труды: Геофизика и космогония. М., 1960.

*Әд.:* Отто Юльевич Шмидт. Жизнь и деятельность. М., 1959; Я к у ш е в а Г.В. Отто Юльевич Шмидт — энциклопедист: Краткая ил. энцикл. М., 1991; М а т в е е в а Л.В. Отто Юльевич Шмидт. 1891–1956. М., 1993; К о р я к и н В.С. Отто Шмидт. М., 2011; Отто Юльевич Шмидт в истории России XX века и развитие его научных идей. М., 2011; Отто Юльевич Шмидт: 120 лет со дня рождения: Книга-альбом. Ярославль-Рыбинск, 2011.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**ШМИДТ** Сигурд Оттович (15.4.1922, Мәскәү — 22.5.2013, шунда ук), тарихчы, педагог, җәмәгать эшлеклесе, тарих фән. д-ры (1965), проф. (1970), Россия мәгариф академиясе академигы (1992), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1989). О.Ю.*Шмидтның* улы. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1944). 1949 елдан Россия гуманитар ун-тында (1991 гә кадәр Мәскәү дәүләт тарих-архив ин-ты). Бер үк вакытта, 1956 дан, СССР ФАнең Тарих ин-тында (1968 дән СССР тарихы ин-ты, 1992 дән — Россия тарихы ин-ты), 2002 дән Славяннарны өйрәнү ин-тында; 1968 дән — Тарих ин-тының Археография комиссиясе рәисе, 2002 дән аның шәрәфле рәисе. «Мәскәү» («Москва») энциклопедиясе баш мөхәррире (1997), 2000 нән — «Мәскәү энциклопедиясе» («Московская энциклопедия») баш мөхәррире. Илдә төбәкне өйрәнү буенча күпкырлы эшчәнлек һәм Россия төбәкне өйрәнүчеләр берлеген (1990) оештыручыларның берсе, берлек рәисе, 2007 дән — шәрәфле рәис. Фәнни эшчәнлегенең төп өлкәсе — 16–18 йөзләр Россия тарихы, мәдәният тарихы, чыганакларны өйрәнү гыйлеме, историография, археография һәм архивчылык гыйлеме, төбәкчелек гыйлеме. Ш.ның 16 йөз Россия тарихына багышланган хезмәтләрендә урта гасырларда Идел буе төбәгенең руслар тарафыннан колонияләштерелүе, Иван IV нең көнчыгыш сәясәте, Казан төбәгендә Россия дәүләтенең хакимият һәм идарә органнары эшчәнлеге, бу тематикага кагылышлы архив документлары үзенчәлекләре тикшерелә. 20 дән артык китап авторы. Урта Идел буе тарихына караган яңа чыганакларны фәнни әйләнешкә кертә. Күптомлы Татар энциклопедиясен эшләү барышында фәнни-методик ярдәм күрсәтә. Митрополит Макарий (2002), акад. Л.С.Лихачёв (2006), «Триумф» (2009) бүләкләре лауреаты. Почёт ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Становление российского самодержавства: Исследование социально-политической истории времени Ивана Грозного. М., 1973; Российское государство в середине XVI столетия: Царский архив и лицевые летописи времени Ивана Грозного. М., 1984; Краеведение и документальные памятники. Тверь, 1992; Археография. Архивоведение. Памятниковедение. М., 1997; Путь историка: Избр. труды по источниковедению и историографии. М., 1997; Общественное самосознание российского благородного сословия: XVII — первая треть XIX в. М., 2002; История Москвы и проблемы москвоведения. М., 2004; «Феномен Фоменко» в контексте изучения современного общественного исторического сознания. М., 2005; Памятники письменности в культуре познания истории России: В 2 т. М., 2007–12.

*Әд.:* Сигурд Оттович Шмидт: Биобиблиогр. указ. М., 2000; Юбилей Сигурда Оттовича Шмидта // Археогр.ежегодник за 2002 год. М., 2004; М е л ь н и ч у к Г.А., С т е п а н о в а Н.В. Юбилей видного историка (С.О.Шмидту — 90 лет) // Библиография. 2012. № 4; Осень патриарха // Наше наследие. 2012. № 102.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**ШНЕПП** Владимир Борисович (17.6.1924, Казан — 21.3.1997, шунда ук), компрессорлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1984), проф. (1986), РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1994). 1942–46 да совет немецлары хезмәт армиясендә — Зөя шәһәренең урман з-дында, «Воркутауголь» комб-тында эшли. Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), Казан компрессорлар з-дында мастер, бүлекнең өлкән инженеры, баш технолог. Компрессорлар төзү махсус КБн (хәзер НИИтурбокомпрессор) оештыручы һәм аның башлыгы — баш конструкторы (1958 дән). 1985 тән бүлек мөдире, 1987 дән консультант. Бер үк вакытта, 1984–88 дә, Казан химия-технол. ин-тының компрессор машиналары һәм корылмалары кафедрасында. Хезмәтләре турбокомпрессорлардагы күчәр көчләре теориясенә һәм шуышу подшипникларындагы ротор тирбәнешләре теориясенә, вакуум техникасына, пневмосистемаларга, машиналарның привод һәм детальләре системасына карый. Ш. лаб.-җитештерү комплексын (мәйданы 10 мең $м^2$) төзүне; унификацияләү нигезендә югары нәтиҗәле машиналар конструкцияләү, аларны тәшкил итүче өлешләрне стандартлаштыру, хисаплау техникасын кулланып исәпләү һәм тикшерү системасын булдыру эшләрен җитәкли. Ш. җитәкчелегендә 200 дән артык төрдәге пешкәкле, үзәктән кугыч, винтлы компрессорлар, ш.и. илдә беренче буларак газ чыгару сәнәгате өчен авиацион күчергечле блок-контейнер тибында-

гы газ кудыру агрегатлары ясала (СССР Дәүләт бүләге, 1980). Уйлап табуга 21 авторлык таныклыгы бар. 1997 дән НИИтурбокомпрессор Ш. исемен йөртә. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХның алтын һәм бронза медальләре; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Конструкция и расчёт центробежных компрессорных машин. М., 1995.

*Әд.:* Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр.справ. К., 2009.

**ШО́ГИН** Алексей Иванович (1779, Зөя ш. — 20.10.1843, Казан), Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре, атаклы граждан. Мещаннар нәселеннән. Приказчик булып эшли, соңыннан тукымалар б-н сату итә. 1813 елда, Казанда беренчеләрдән булып, «остинд» яулыклар, сәрфинкә, комач, китайка тукымалары тукылган текстиль ф-касына нигез сала (1815 тә, 1827 дә фабрика яна. Ш. аны ике тапкыр торгыза). Ш. фабрикасында җитештерелгән тукымалар югары сыйфатлы була, Эрбет, Түбән Новгород, Минзәлә, Оренбург ярминкәләрендә күпләп сатыла. Казанда Ш. Гостиный дворның ике кибетендә сату итә. 1824 тә Казан шәһәр думасы гласные, йорт бәяләрен яңадан карап чыгу буенча комиссия әгъзасы, бургомистр, Благовещение соборының чиркәү старостасы. Күп кенә акчасын чиркәүләр файдасына сарыф итә.

*Л.М.Свердлова.*

**ШОДА́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 40 *км* төньяктарак, Кугубор елгасы буенда. 2010 елда 331 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Драматург М.*Фәйзи* музее. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чабата үрү, олаучылык, сәүдә б-н шөгыльләнә. Донбасс күмер шахталарына һәм Урал, Алдан, Лена алтын приискларына китеп эшлиләр. 20 йөз башында Ш.да волость идарәсе урнаша; 2 мәчет (1902 дә төзелгән 2 нче җамигъ мәчет бинасы сакланган), 2 мәдрәсә, 3 су тегермәне, берничә кибет була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2552,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Шода волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1795 тә — 240, 1834 тә — 445, 1859 да — 667, 1884 тә — 948, 1905 тә — 1216, 1920 дә — 1413, 1926 да — 1394, 1938 дә — 1042, 1949 да — 718, 1958 дә — 603, 1970 тә — 484, 1979 да — 390, 1989 да — 344, 2002 дә — 368 кеше. Сов. Союзы Герое Х.С.*Сабировның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ш. б-н бәйле.

**ШОЛГАННА́Р** (Neomys), җир тычканнары семьялыгыннан имезүчеләр ыругы. 2–3 төре билгеле, Евразиядә таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — гади шолган яки су тычканы (N. fodiens) теркәлгән. Кама алдында һәм Кама арьягында очрый. Су буйларында, сазлыкларда, дымлы урманнарда оялый. Куышлыклардагы яки тычкансыман кимерүчеләр, вак су тычканнары, ондатра өннәрендәге ояларда яши. Гәүдәсенең озынлыгы 7,5–10 *см*, койрыгы 6,5–7 *см*; авырлыгы 10–22 *г*. Мехы юка, куе, бәрхетсыман, аркасында кара төстә, бүксәсендә көмешсыман-ак; су үткәрмәүче тоташ йон капламыннан тора. Борыны хортум булып сузылган. Ш. җир-су яшәү рәвешенә яраклашканнар, яхшы йөзәләр һәм чумалар. Бармак кырыйлары һәм аяк табаны каты төкчәләр б-н каймаланган; колак кабырчыклары суда томаланалар. Елына берничә тапкыр 7–9 бала китерә. Яшәвенең беренче елында җенси яктан өлгерә. Яңгыр суалчаннары, бөҗәкләр һәм аларның личинкалары, кечкенә моллюсклар, балык уылдыгы һәм маймычлар б-н туклана. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Гади шолган.

**ШОМА́ КӨПШӘ́** (Archangelica), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан ике яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 10 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында очрыйлар. ТР терр-ясендә бер төре — дарулы Ш.к (A. officinalis) таралган. Барлык респ-када дымлы урман буйларында, кисенделәрдә үсә. 120–150 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамырчасы кыска, вертикаль, коңгырт, күпсанлы өстәмә тамырлы, сынган урынында аксыл яки саргылт сөтчел сок бүленеп чыга. Сабагы туры, куыш, күгелҗем куныклы. Яфраклары чиратлашкан, җиңсәле, икешәр һәм өчәр каурыйсыман. Чәчәкләре вак, саргылт-яшькелт төстә, шарсыман катлаулы эре чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — икеорлыкча. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Чәчәк атып җимеш биргәч үсемлек үлә. Орлыктан һәм вегетатив ысул б-н үрчи. Составында кумарин һәм эфир майлары булганлыктан үсемлекнең барлык өлешләре, аеруча тамырчасы һәм җимешләре хуш исле (тышкы билгеләре охшаш булган курай үләненнән аермалы буларак). Тамырчасында крахмал, сумала, органик к-талар, дуплау матдәләре бар. Медицинада тамырчасы һәм тамырлары төнәтмәсе ашкайнатуны яхшырту, тир чыгару һәм ялкынсынуга каршы чара буларак файдаланыла. Бәвел кудыру чәйләре составына керә. Яшь яфраклары һәм сабагы аш-су әзерләүдә кулланыла. Баллы үсемлек. Аю һәм кондызлар өчен азык булып тора. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Дарулы шома көпшә.

**ШОМАЛА́К** (Laserpitium), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, башлыча, Урта диңгез буенда таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — Пруссия Ш.ы (L. prutenicum) ара-тирә Кама арьягында очрый. Нарат һәм имән урманнарында үсә. 30–120 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыры озын, вертикаль. Сабагының аскы өлеше нык тармаклы, өске өлеше шома. Яфраклары төкчәле озын сапта, икешәр каурыйсыман. Чәчәкләре ак, катлаулы чатыр чәчәк төркемендә. Җимеше — канатсыман кабыргалы иенке җимешлек. Июнь–августта чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Тамырларында гликозид, флавоноид, алкалоидлар бар. Ш.тан ясалган дарулар ашказаны, бавыр авырулары вакытында һәм бәвел кудыру чарасы буларак файдаланыла. Составында эфир майлары булган декоратив үсемлек.

**ШОМАЧЫКЛА́Р** (Notonectidae), су кандалалары семьялыгы. 200 гә якын төре билгеле, аларның күпчелеге тропикларда тереклек итә. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади шомачык (Notonecta glauca) очрый. Ш.ның барлык тереклек циклы су мохите б-н бәйле. Гәүдәсе һаваның каршылыгына аз бирешүчән формада, озынлыгы 10 *мм* дан озынрак. Канат өслекләре тонык, өске ягы кабарынкы, аркасы яшькелт төстә һәм су б-н юешләнми, шунлыктан су астында кандала ялтырап күренә. Арткы аяклары йөзәргә яраклашкан. Ш. арка ягы аста килеш төптән су өслегенә кадәр күтәреләләр, бирелдә корсакларының арткы очын судан чыгарып атм. һавасы җыялар. Актив ерткычлар, чукмарбаш, маймычлар б-н туеналар. Балыкчылыкка зыян китерәләр.

**ШОМБА́Й**, татар халкының көнкүреш әкиятләре персонажы. Һәрвакыт усал һәм саран байны алдарга, үз мәнфәгатьләрен якларга юл тапкан җитез һәм тапкыр хезмәтче. Тапкырлыгы б-н үзенә каршы кешене көлке хәлдә калдыручы уңай персонаж («Шомбай», «Карт белән карчыкның Шомбай хезмәтчедән күргән хезмәтләре» һ.б. әкиятләр). Беренче тапкыр Ш. турындагы әкиятләрне рус телендә М.А.Васильев «Татар халык әдәбияты ядкәрләре» («Памятники татарской народной словесности», 1924) җыентыгында «Хәйләкәр хезмәтче» («Хитрый работник») исеме б-н бастыра.

*Әд.:* Халык иҗаты. К., 1938; Татар халык әкиятләре. К., 1956; Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1981. 3 кит.; Балаларга — әкиятләр. К., 2000.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ШОМБИЯ́ ҮЛӘНЕ́**, з а р а з и х а (Orobanche), шомбиячалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык паразит үсемлекләр ыругы. 150 дән артык төре билгеле. Төньяк ярымшарның уртача һәм субтропик поясларында таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре очрый. Бартлинг Ш.ү. (O. bartlingii) респ-ка терр-ясенең һәр җи-

рендә таралган, урман аланнарында, үләнле тау битләрендә үсә. Бака кабырчыгы тамырларында һәм кайбер башка чатыр чәчәклеләрдә паразитлык итәләр. Аксыл чәчәкле Ш.ү. (O. pallidiflora) Кама арьягында очрый, болыннарда, куаклар арасында, грунт сулары чыккан урыннарда үсә. Бакча билчәне тамырларында паразитлык итә.

15–60 *см* биеклектәге хлорофиллсыз үсемлек. Ш.ү. имгечләре б-н (калын җепселләр, алар эволюция процессы нәтиҗәсендә тамырларга әвереләләр) башка үсемлекләрнең тамырларына ябышып, аларда паразитлык итә. Сабаклары калын, төбе бүлбесыман калынаеп тора; яфраклары урынына — көрән тәңкәчекләр. Чәчәкләре аксыл-сары, башак чәчәк төркемендә. Июль–августта чәчәк ата. Җимеше — ике капкач б-н ачылучан, бик күп вак орлыклы (бер тартмада 2 меңгә кадәр орлык) тартмачык, җил б-н җиңел таралалар, тереклек үзлеген 8–10 елга кадәр саклыйлар. Куркыныч паразит. Көрәш чаралары: агротехника кагыйдәләрен саклау, а.х. культураларының Ш.ү.нә каршы торучан сортларын игү.

**ШОМБЫ́Т** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 43,9 *км*. Бассейнының мәйданы 473 *км*². Балык Бистәсе р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Шомырбаш авылыннан 4 *км* читтәрәк урман массивында урнашкан, тамагы Тукай посёлогыннан (даими яшәүчеләр юк) 3 *км* көньяктарак. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычының терәү сулары астында. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. Нигездә, караңгы ылыслы-киң яфраклы урманнар өстенлек итә. Ш. талгын гына көньякка Кама елгасына таба авыш җиңелчә калкулыклы тигезлектән ага. Үзәне асимметрияле, сулъяк сөзәклеге текәрәк; тамак өлешендә асимметрия бик күзәтелми, чөнки бу урында елга Каманың түбәнрәк булган тигез тугаеннан ага. Елга юлы бормалы, тармакланмаган. Ш.ның 14 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Кече Шомбыт (20,8 *км*) — уң, Пимәр (8,2 *км*) — сул кушылдык. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,33 *км/км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Бассейнының төрле өлешләрендә җир асты сулары б-н туену модуле 1 дән 10 *л/с·км*² га кадәр. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы



Шомбыт елгасы.

94–116 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80–95 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана, уртача 27 көн дәвам итә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,29 *м*³*/с*. Ш. ноябрь уртасында туңа. Боз катламы тотрыклы, уртача 150 көн дәвам итә. Суы сульфат-гидрокарбонат-кальцийлы типта,югары агымында язын уртача йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), урта һәм түбән агымнарында уртача каты (3–6 *мг-экв/л*); җәен һәм кышын суының иң аз вакытында бөтен озынлыгында каты. Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Ш. бассейнында суының гомуми күләме 1,82 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару, а.х. һәм сәнәгать пр-тиеләрен су б-н тәэмин итү өчен файдаланыла. Ш. — ТРның табигать истәлеге (1978).

*О.Н.Урбанова.*

**ШОМБЫ́Т** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 40 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасы буенда. 2010 елда 416 кеше (руслар) яши. Спирт з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1730–40 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шомбыт аракы з-ды, Воронцов з-ды, Богородский исемнәре б-н билгеле. 1861 елгы реформага



Шомбыт авылындагы Владимир Богородица чиркәве. 1787.

кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Владимир Богородица чиркәве (1787 дә төзелә; архит-ра истәлеге; хәзерге көндә дә эшли), чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), фельдшерлык пункты, авыруларны кабул итү бүлмәсе, аракы, ат, кирпеч з-длары, су тегермәне, такта яру җайланмасы, постау басу йорты, 2 тимерче алачыгы, 7 сыраханә, казна шәраб кибете, чәйханә һәм аеклык җәмгыяте уку залы була; сишәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 330 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 201 ир-ат; 1859 да — 972, 1897 дә — 1428, 1908 дә — 1347, 1920 дә — 1323, 1926 да — 1303, 1938 дә — 1683, 1949 да — 2039, 1958 дә — 2700, 1970 тә — 1016, 1989 да — 416, 2002 дә — 480 кеше.

**ШОМБЫ́Т АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, Балык Бистәсе р-ны терр-ясендә, Куйбышев сусаклагычының уңъяк ярындагы Шомбыт елгасының түбән агымында урнашкан. Урманнар. Мәйданы 12,5 мең *га*. 1963 елда кондыз популяциясен торгызу максатында оештырыла. Аучылык фаунасының төр составы: поши, кабан дуңгызы, кондыз, төлке, селәүсен, сусар, Америка чәшкесе, ондатра, бурсык, ак куян һәм үр куяны, тиен, сасы көзән, көртлек, божыр, су кошлары.

**ШО́МИН** Николай Михайлович (1.5.1914, Түбән Новгород — ?), корабльләр төзүче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1949). Горький индустриаль ин-тын тәмамлаганнан соң (1938), Суднолар төзү сәнәгате министрлыгының Үзәк КБда (Горький ш.) эшли: инженер, баш конструктор урынбасары (1938–49), әйдәп баручы конструктор (1957–66), баш конструктор (1966–72), проектларның баш конструкторы — 1 нче категорияле конструктор (1972–81). 1949–57 елларда Яшел Үзән суднолар төзү з-дының Үзәк КБда баш конструктор урынбасары. Дәүләт бүләге корабльләрне агымлы-позицион төзү проектын эшләгәне өчен бирелә. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШОМЫРБА́Ш** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 48 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 172 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.да волость идарәсе урнаша; Пётр һәм Павел чиркәве, земство (1900 дә ачыла) һәм Халык мәгариф министрлыгы мәктәбе, фельдшерлык пункты, су тегермәне, ярма яргыч, казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 915 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 558, 1897 дә — 820, 1908 дә — 911, 1920 дә — 904, 1926 да — 683, 1938 дә — 936, 1949 да — 678, 1958 дә — 674, 1970 тә — 508, 1989 да — 282, 2002 дә — 205 кеше.

**ШОМЫ́РТ** (Padus), роза чәчәклеләр семьялыгыннан агач, сирәк кенә куаклар ыругы. 30 га якын төре билгеле, Төньяк ярымшар-

ның уртача поясында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 4 төре бар. Гади Ш. (P. avium) киң яфраклы һәм катнаш урманнарда, елга тугайларында үсә. Маак Ш.ы (P. maackii), пенсильван Ш.ы (P. pensylvanica), виргин Ш.ы (P. virginiana) декоратив һәм җимеш үсемлеге буларак Көнбатыш Кама алдында үстерелә. Аеруча гади Ш. киң таралган. 15 *м* га кадәр биеклектәге агач, куе ябалдашлы һәм яргаланган коңгырт-кара кабыклы (әчкелтем исе бар). Яфраклары кара-яшел, эллипссыман, аз гына җыерчыклы,



Гади шомырт.

кырыйлары очлы тешәүле. Чәчәкләре хуш исле, 12 *см* га кадәр озынлыктагы иенке чукка җыйналган. Җимешләре — шарсыман кара ялтыравыклы каты төшчә (ашарга яраклы). Майда чәчәк аталар. Август–сентябрьдә җимеш бирәләр. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (үсенте, чыбыкча, үрентеләрдән) үрчиләр. Ш. җимешләрендә шикәр, дуплау һәм пектин матдәләр, органик к-талар, флавоноидлар, микроэлементлар, яфракларында эфир майлары, кабыгында дуплау матдәләре бар. Халык медицинасында яфракларыннан әзерләнгән төнәтмә ашказаны-эчәк тракты бозылганда, кабыгының төнәтмәсе бәвел кудыру һәм тире чыгару чарасы буларак файдаланыла. Яфраклары фитонцид үзлекләргә ия. Ш. — кыйммәтле урман токымы: туфрак структурасын яхшырта, елга ярларын һәм тау битләрен ныгыта. Шәһәр шартларында да яхшы үсә. Тыгыз, кызыл үзагачы агач эшләнмәләр җитештерүдә хезмәт итә. Барлык төрләре дә баллы.

**ШОМЫРТКОҢГЫЗЛА́Р** (Histeridae), төрле азык б-н туклanучылар асотрядыннан коңгызлар семьялыгы. Якынча 3,5 мең, РФдә 100 дән артык төре билгеле. Татарстан терр-ясендә һәр җирдә очрый. 7–10 *мм* озынлыктагы бертөсле шомырткоңгыз (Hister unicolor) һәм 5–8 *мм* лы дүрт таплы шомырткоңгыз (H. Quadrinotatus) респ-ка өчен гадәти төрләр. Гәүдәсе тыгыз, гадәттә, кабарынкы, озынча түгәрәк яки түгәрәк. Мыекчалары буынлы, озын хәрәкәтчел буынлы һәм тыгыз чукмарсыман. Башы алгы күкрәккә нык кына ябышып тора, аның эченә дә кереп китәргә мөмкин. Канат өслекләре кыскарган, корсак өлешен тулысынча капламыйлар, аяклары казуга җайлашкан. Ш. куркыныч янаганда мыекча һәм аякларын җыялар һәм үлгән кебек яталар. Күпчелеге ерткычлар; олы коңгызлар һәм личинкалары, башлыча, башка бөҗәкләрнең личинкалары, кайберләре гөмбәләр б-н туеналар. Күп төрләре үләксәләрдә, тирестә, тизәктә, черүче үсемлек калдыкларында; күбесе кайры астындагы бөҗәкләр юлында һәм үзагачта; кайберләре кош ояларында, имезүчеләрнең өннәрендә яки кырмыска ояларында яшиләр. Зарарлы бөҗәкләрне юк итәләр.

*А.К.Жеребцов.*

**ШОМЫРТЛЫ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 23 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әдәм елгасы буенда. 2010 елда 135 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб. 18 йөз уртасында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.да җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Емелькино авылын да кертеп) 960 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан — Алексеев, 1977 нең 29 августыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1859 да — 150, 1908 дә — 354, 1920 дә — 311, 1926 да — 274, 1938 дә — 283, 1949 да — 228, 1958 дә — 305, 1970 тә — 370, 1979 да — 320, 1989 да — 212, 2002 дә — 166 кеше.

**ШОМЫРША́ РАЙОНЫ́**, *Чуаш Республикасының* көньягында урнашкан. 1927 елның 5 сентябрендә оештырыла. Мәйданы — 799,1 *км*². Үзәге — Шомырша авылы (Чабаксардан 160 *км* көньяктарак). Халкы — 12569 кеше (2017). 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 1478 кеше. Алар, тупланып, Өч Балтай (1111 кеше), Байтирәк (252), Асан (96), Чепкас-Никольское (19) авылларында яшиләр. «Яшьлек» балалар фольклор коллективы (Байтирәк а., 2004 тән), Өч Балтай (1905 тә төзелә; тарих һәм мәдәният истәлеге), Байтирәк (1909), Асан (1998) авылларында мәчетләр эшли. Өч Балтай, Чепкас-Никольское, Байтирәк авыллары мәктәпләрендә татар теле фән буларак өйрәнелә. 2008 дә Шомырша р-нында Татар мәдәнияте көннәренә багышланган «Татар халкының рухи байлыгы» фестивале үткәрелә.

**ШОНАСИ́** Габдулла Сабир улы (псевд., чын фамилиясе Ибраһимов) (1885, Оренбург губ. Троицк ш. — 11.3.1938, Казан), педагог, җәмәгать эшлеклесе. «Хөсәения» мәдрәсәсендә (Оренбург ш.), «Әл-Әзһар» ун-тында (Каһирә, Мисыр) укый. 1909 елда «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. 1912 дән Уфада: «Галия» мәдрәсәсендә укыту бүлеге мөдире, 1915–18 дә «Госмания» мәдрәсәсендә. 1920–30 елларда Казан ун-тында, Шәрекъ пед. ин-тында, А.х һәм урманчылык ин-тында татар теле укыта. Бер үк вакытта, 1930 дан, ТАССР Мәгариф халык комис-тында методист һәм лектор. 1910–17 дә химия, табигать белеме, геогр. буенча уку ярдәмлекләрен бастыра, алар бернич тапкыр кабат нәшер ителәләр һәм яңа ысуллы татар мәктәпләрендә киң кулланылалар. Татар урта уку йортлары өчен химия, биол., физика, табигать белеме буенча дәреслекләр авторы. Татар теленең фәнни лексикасын эшли. 2 нче Бөтенроссия мөселманнар корылтаенда (июль, 1917) Ш. актив рәвештә милли-мәдәни автономия булдыру өчен чыгыш лар ясый, шуның өчен милләтчелектә гаепләнә. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Хикмәте табигыя дәреслеге. Уфа, 1916; Җан һәм тереклек. Уфа, 1923; Хайваннарның һәм кешеләрнең яралуы. К., 1925.

**ШОНГАТЫ́** елгасы, Идел алдында, Үләмә елгасының (Зөя елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Идел буе калкулыгыннан, Тәтеш р-нында ага. Озынлыгы 9,4 *км*. Бассейнының мәйданы 50,3 *км*². Елга башы Кече Әтрәч авылыннан 2,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Ямбакты авылыннан көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 185 *м*, тамагыныкы — 77 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Ш.ның 1,8 дән 4,2 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,49 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 147 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 130 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,035 *м*³/*с*. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ШОНГАТЫ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 12 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 119 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1644 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ильинский исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, тире эшкәртү, чүлмәк ясау, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Илья чиркәве, иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, земство мәктәбе (1868 дә ачыла) һәм хастаханәсе, вак кредит учреждениесе, вет. фельдшерлык пункты, керосин кибете, су һәм 9 җил тегермәне, ярма яргыч, салат з-ды, йон-тукыма ману, 6 чүлмәк ясау, 2 тире эшкәртү, йон тетү, 2 май язу йортлары, 5 тимерче алачыгы, 8 ашлык амбары, ашханә, 2 сыраханә, 2 чәйханә, 1 казна шәраб һәм 10 вак-төякләр кибете була; сишәмбе базары, 2 ярминкә (28 — 31 май һәм 18 — 20 сентябрь) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5483,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Ильинский-Шонгат волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең

4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 388 ир-ат; 1859 да — 1502, 1897 дә — 2882, 1908 дә — 3207, 1920 дә — 2751, 1926 да — 2899, 1938 дә — 1656, 1949 да — 1113, 1958 дә — 758, 1970 тә — 426, 1979 да — 260, 1989 да — 140, 2002 дә — 170 кеше. Ш. янында 13 — 14 йөзләрдәге Шонгат шәһәрлеге калдыклары сакланган.

**ШОНГАТЫ́**, урта гасырлар (13–14 йөзләр тирәсе) болгарлар шәһәре. Ш.ның археол. хәрабәләре Тәтеш р-ны Олы Әтрәч авылы янында урнашкан. 14 йөз кабер ташлары булган мөселман зираты сакланган.

**ШОНГАТЫ́ КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Үләмә елгасының (Зөя елгасы кушылдыгы) уңъяк ярында, Апас р-ны Шонгаты авылы янында. Ш.к. истәлекләре И.А.Износков (19 йөз), Н.Ф.Калинин һәм А.Х.Халиков (1949), Р.Г.Фәхретдинов (1960 еллар) тарафыннан тикшерелә. Таш һәм бронза гасырлар истәлекләрен, Болгар культурасына нисбәтле шәһәрлекне, 2 авыллыкны һәм каберлекне һ.б.ны үз эченә ала. Болгар шәһәрлеге елга буендагы тәбәнәк киртләчтә, Шонгаты авылыннан 0,5 *км* ераклыкта урнашкан, мәйданы 40 мең *м*² чамасы. Ш.к. терр-ясендә чакматаш эшләнмәләр, керамика кисәкләре, кораллар табыла (ТР Милли музее фондларында һәм Финляндиядә В.И.Заусайлов тупланмасында сакланалар).

*Әд.:* Калинин Н.Ф., Халиков А.Х. Итоги археологических работ за 1945–1952 гг. К., 1954; Ефимова А.М. Каталог археологических коллекций. К., 1980. Вып. 2; Археологическая карта Татарской АССР. Предволжье. К., 1985.

**ШОНТАЛЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кама елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 36,6 *км*. Бассейнының мәйданы 459,1 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән ага. Елга башы Чистай р-ны Чирүле Шонталы авылыннан 5 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Речной авылыннан 4 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Ш.ның 1,6 дан 16,6 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Болак (9,3 *км*), Тиган (16,6 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,2 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле югары агымында 0,1–0,25 *л/с·км*², бассейнының түбән өлешендә 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 97 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,133 *м*³*/с*. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Ш. бассейнында суының гомуми күләме 2,6 млн. *м*³ булган 6 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШОНТАЛЫ́ РАЙОНЫ́**, *Самара өлкәсенең* төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1935 елда Денис р-ны буларак оештырыла, 1940 тан хәзерге исемен йөртә. Мәйданы — 1338,2 *км*². Үзәге — Шонталы тимер юл станциясе (Самарадан 204 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 15597 кеше (2017). 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 3545 кеше. Алар, тупланып, район үзәгендә (1600 ләп кеше), Денис (1342), Татар Әбдекие (476), Карабиккол (100 ләп кеше) авылларында яшиләр. Ш.р. терр-ясенә татарлар 17 йөз ахыры — 18 йөз башында килеп урнаша. 1730 елларда, *Кама аръягы чик сызыгы* төзелү б-н бәйле рәвештә, күчеп килүчеләрнең саны арта. Бу чорда Ш.р.ның иң зур татар авылы — Денис (1917 гә кадәр 1000 ләп хуҗалык, 4 мәчет һәм мәдрәсә) төзелә. Шонталы «Нур» район татар җәмгыяте (Шонталы тимер юл станциясе; 1997 дән), «Чулпан» халык фольклор һәм «Мизгел» балалар (Денис а.) ансамбльләре; район үзәгендә, Денис (2), Татар Әбдекие, Карабиккол авылларында мәчетләр эшли. Денис һәм Татар Әбдекие авыллары мәктәпләрендә татар теле фән буларак өйрәнелә. *Сабан туе* үткәрелә. 1960 та СДБ-4 тибындагы үзйөрешле баржа б-н 49 көнлек дрейфта катнашкан старшина Ә.Р.*Җиһаншинның*, спортчылар Һ.Х.*Бикташев* һәм Р.И.*Кашаповның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ш.р. б-н бәйле.

**ШО́ФМАН** Аркадий Семёнович (15.11.1913, Витебск губ. Городок ш. — 7.10.1993, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1964), проф. (1965), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1983). 1930–33 елларда Могилёв пед. ин-тында укый. Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң (1938), шунда ук эшли. 1940 тан гомуми тарих каф. мөдире, 1943 тән Ашхабад пед. ин-тының тарих ф-ты деканы. 1948–86 да Казан ун-тының гомуми тарих каф. мөдире, 1986 дан проф.-консультант. «Антик дөнъямбе» фәнни семинарын булдыруның башлап йөрүчесе һәм аның җитәкчесе. Хезмәтләре Македония, эллинистик Греция, Россиядә һәм чит илләрдә антик чорны өйрәнү гыйлеменә карый. «Антик тарих историографиясе» («Историография античной истории», М., 1980) дәреслегенең берничә бүлеге, Казанда эшләгән антик тарих белгечләре Ф.Г.Мищенко һәм М.М.Хвостов турындагы ике монография авторы. Марксизм-ленинизмга нигез салучыларның антик үткәннәргә карашларын тикшерә («Маркс, Энгельс, Ленин антик җәмгыять хакында» — «Маркс, Энгельс, Ленин об античном обществе», 1971).

Хезм.: Казанский период жизни и деятельности Доржи Банзарова. Улан-Удэ, 1956; История античной Македонии: В 2 ч. К., 1960–63; Фёдор Герасимович Мищенко. К., 1974; Восточная политика Александра Македонского. К., 1976; Михаил Михайлович Хвостов. К., 1979; Распад империи Александра Македонского. К., 1984.

*Әд.:* Античность: события и исследователи. К., 1999; Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999.



А.С.Шофман.

**ШӨГЕ́Р** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Урман Чишмәсе елгасы буенда. 2010 елда 2096 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 88%) яши. Төзелеш пр-тиеләре, тегү ф-касы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, 2 китапханә, Мәктәптән тыш эшләр үзәге, участок хастаханәсе, вет. шифаханәсе. Мәчет. 1931 дә Шөгер р-ны үзәге посёлогы буларак төзелә, 1950 нең 11 гыйнварыннан — шәһәр тибындагы посёлок, 1959 ның 12 октябреннән — Лениногорск р-нында, 2004 нең 25 октябреннән — авыл. Халык саны: 1989 да — 2 мең, 2002 дә — 2,2 мең кеше.

**ШӨГЕ́Р АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, Лениногорск р-ны терр-ясендә, шәһәр тибындагы Шөгер посёлогыннан төньяктарак Чишмә елгасы үзәненең уңъяк яры сөзәклегендә урнашкан. Урманнар, басулар; терр-ясеннән Каратай, Куак, Баллы һ.б. елгалар ага. Мәйданы 29,7 мең *га*. 1971 елда сөркә-байбаклар санын торгызу максаты б-н оештырыла. Аучылык фаунасының төр составы: поши, ак куян һәм үр куяны, ондатра, төлке, сусар, Америка чәшкесе, сасы көзән һәм дала көзәне, селәүсен, суер, көртлек, боҗыр, соры көртлек.

**ШӨГЕ́Р БИ́ТУМ ЧЫГАНАГЫ́**, Шөгер авылы янында (Лениногорск р-ны). Татарстан терр-ясендә иң борынгы чыганакларның берсе. 18 йөздән билгеле. Битумның сәнәгый ятмалары 1870 елда ачыклана. Баланс запасы 192 мең *т* (1949). Пермь системасы Уфа ярусы утырмаларындагы төп ятмалар битумлы комташлардан тора. Сәнәгый катламның уртача яту тирәнлеге 93 *м*, калынлыгы 1,5–5 *м*. Битумга туенганлык 3,2%. Күбесенчә битум сумала-асфальт тибында, тыгызлыгы 0,984 *т/м*³, составында V, Ni һ.б. элементлар бар.

*Б.В.Успенский.*

**ШӨГЕ́Р НЕФТЬ ЧЫГАНАГЫ́**, к. *Ромашкино нефть чыганагы.*

**ШӨГЕ́Р РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1930 елның 10 августында оештырыла. Үзәге — Шөгер авылы. 1920 гә кадәр терр-ясе Самара губернасының Бөгелмә өязендә, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. Оешкан көненнән районга 32 авыл советы, 57 торак пункт керә, аларда 42549 (татарлар — 29805, руслар — 4043, башка милләтләр — 8701) кеше яши. 1935 нең 10 февралендә Ш.р.ның бер өлеше яңа оешкан Яңа Писмән р-нына бирелә. 1940 та районның мәйданы — 1292 *км*², халык саны — 38,8 мең кеше; 22 авыл советы, 52 торак пункт керә. 1956 да район 1213,2 *км*² җир били, 2 шәһәр һәм 19 авыл советын, 53 торак пунктны берләштерә. 1959 ның 16 октябрендә Ш.р. таркатыла, биләмәсе Лениногорск р-нына бирелә.

**ШӨГЕ́РОВА** Галимә Әхмәткари кызы (8.11.1953, Омск ш.), спортчы, тренер (нәфис гимнастика), СССРның атказ. спорт остасы (1973), РСФСРның атказ. тренеры

(1989). Омск физик культура ин-тын тәмамлый (1975). Спорт б-н 1962 елда «Красная звезда» СК (Омск) каршындагы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә шөгыльләнә башлый, тренеры — Г.П.Горенкова. 1969–70 тә «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте (Омск), 1971 дән «Зенит» иреклеспорт җәмгыяте (Омск) өчен чыгыш ясый. Дөнья (1973), Европа (1978), СССРның (1970, 1972–73) абсолют чемпионы, дөнья (1969, туп, сикергеч б-н күнегүләрдә; 1973, булава, туп, тасма б-н — төркемдә; 1977, сикергеч, бөҗра, туп б-н — төркемдә), Европа (1978, сикергеч, тасма б-н) чемпионатларында алтын медальләр яулый, дөнья (1969, көмеш — күп төр ярышларда һәм төркемдә; 1971, көмеш — төркемдә сикергеч б-н, бронза — тасма б-н; 1977, көмеш — күп төр ярышларда һәм тасма б-н), Европа (1978 , көмеш — туп б-н) чемпионатларында призлар ала, СССР кубогы иясе (1974). 1979–82 дә Физик культура һәм спорт өлкә ком-тында тренер-инструктор, 1983–92 дә — «Красная звезда» СК каршындагы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер (Омск). Шәкертләре арасында — С.Бабий, атказ. спорт остасы, төркемле күнегүләрдә дөнья һәм Европа чемпионы (1988–89). Россиянең Олимпия ком-ты (1990–97), Бөтенроссия нәфис гимнастика федерациясе (1992–2008) вице-президенты. Халыкара категорияле судья. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**ШӨГЕРЧӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Чишмә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 13,8 *км*. Бассейнының мәйданы 53 *км*². Елга башы Әлмәт р-ны Красная Поляна авылыннан көнчыгыштарак урман массивында, тамагы Яңа Чишмә р-ны Андреевка авылыннан төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 63 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Ш.нең 1 дән 1,2 *км* га кадәр озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 *км/км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,037 *м*³/*с*. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 0,5 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШӨГЕРЧӘ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 75 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шөгерчә елгасы буенда. 2010 елда 81 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1839 дан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстиннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, арба, чана, тәгәрмәч, тугым, чана табаны, тәртә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.дә чиркәү-приход мәктәбе (1895 тә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 738 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1859 да — 257, 1897 дә — 510, 1908 дә — 614, 1920 дә — 630, 1926 да — 513, 1938 дә — 467, 1949 да — 369, 1958 дә — 312, 1970 тә — 286, 1979 да — 196, 1989 да — 112, 2002 дә — 99 кеше.

**ШӨКРӘЛЕ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чаллы елгасы (Каманың сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 86 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1650–51 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре һәм асабалар катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.дә мәчет, мәктәп, ярма яргыч, тимерче алачыгы, ашлык саклау-сату һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1243,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1816 да — 33 ир-ат; 1834 тә — 253, 1870 тә — 634, 1897 дә — 961, 1906 да — 757, 1920 дә — 993, 1926 да — 563, 1938 дә — 607. 1949 да — 364, 1958 дә — 237, 1970 тә — 216, 1979 да — 190, 1989 да — 75, 2002 дә — 92 кеше.

**ШӨЛДЕ́Р ЧӘЧӘ́К**, кыңгырау гөл (Adenophora), кыңгырау чәчәкләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Дөнья флорасында 50 төре билгеле, күбесе Көнчыгыш Азиядә таралган. ТРда бер төре — лалә яфраклы Ш.ч. (A. liliifolia) Кама аръягында, болын, кыр, урманнарда үсә. Җилпәзәсыман юан тамырлы. Сабагы туры, кабыргалы, 80–100 *см* биеклектә. Яфраклары аз гына төкчәле, кырыйлары эре тешәүле, аскылары — сапчыл, йомырка- яки эллипссыман, өскеләре — утырма, ланцетсыман, очлы. Чәчәкләре зәңгәр, кайвакыт аксыл-алсу, себеркәч чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — тартмачык. Июль–августта чәчәк ата. Ш.ч.не декоратив үсемлек буларак үстерәләр.

**ШӨЛДЕРУ́Т** (Rhinanthus), сыраҗчалар семьялыгыннан берьеллык үләннәр ыругы; ярымпаразит чүп үлән. 50 төре билгеле. ТР терр-ясендә 5 төре үсә: җәйге Ш. (R. aestivalis), канатсыз Ш. (R. apterus), көзге Ш. (R. serotinus), кечкенә Ш. (R. minor), язгы Ш. (R. vernalis). Барлык җирдә — болыннарда, урман аланнарында, көзге арыш һәм бодай чәчүлекләрендә таралган. Яфраклары ланцетсыман, капма-каршы урнашкан, сабакны чолгап үсәләр, читләре вак тешәүле. Тамырлары җитлекмәгән, кыргый һәм культурадагы кыяклыларның тамырларына ябышалар һәм аларның соклары б-н тукланалар. Сабаклары дүрт кырлы. Август–сентябрьдә чәчәк ата. Чәчәкләре 2 *см* озынлыкта, ачык-сары, башаксыман чәчәк төркеменә җыелган. Җимеше — шарсыман орлыклы тартмачык. Орлыктан үрчи (бер үсемлектә берничә йөзгә кадәр орлык өлгерә, аларның яшәүгә сәләтлелеге 1 елдан артмый). Өлгергән орлыклары җимешенә бәрелеп шалтырыйлар (исеме шуннан). Ш. агулы (составында алкалоид ринантин бар). Көрәш чаралары: орлыклык материалны чистарту, болындагы үләннәрне орлыклары өлгергәнче чабып алу, гербицидлар куллану.

**ШӨЛДИ́ КОШЛА́Р** (Charadriidae), шөлдисыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. 60 тан артык төре билгеле. Башлыча, Евразия, Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә 8 төре яши. Тулес (Pluvialis squatarola), алтын шөлди (Pluvialis apricaria), таш актаручы шөлдиләр (Arenaria interpres), галстуклы шөлди (Chettusia gregaria) һ.б. очып үтүләр вакытында очрый. Тәкәрлек (Vanellus vanellus), яңгыр чыпчыгы



Шөлди кошлар:
1. Яңгыр чыпчыгы;
2. Тәкәрлек.

(Charadrius dubius) — оя коручы төрләр. Ачык урыннарда оялыйлар. Кечкенә һәм уртача зурлыктагы кошлар. Авырлыгы 20–60 *г*. Башы чагыштырмача зур. Томшыгы кыска, нык. Күп кенә Ш.к.ның канатлары озын, очлы, алар тиз очуга җайлашкан. Аяклары кыска. Оясы — коры җир өстендә, тирән булмаган чокырчыклар рәвешендә. 1–4 йомырка сала. Бөҗәкләр, аларның личинкалары, сирәк кенә орлык һәм җиләкләр б-н туклана. Тәкәрлек — спорт аучылыгы объекты.

**ШӨМЛӘ́Н** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 43 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 3 кеше (руслар) яши. 18 – 19 йөзләрдә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.дә вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 168 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Күлле Киме волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1859 да — 73, 1897 дә — 149, 1908 дә — 244, 1920 дә — 211, 1926 да — 248, 1938 дә — 296, 1949 да — 236, 1958 дә — 148, 1970 тә — 95, 1989 да — 38, 2002 дә — 9 кеше.

**ШӨПШӘЛӘ́Р**, чагучы элпәканатлы бөҗәкләр өсотряды төркеме. Күкрәгендә ике пар үтә күренмәле элпә канатлары бар, корсагы

күкрәгеннән хәрәкәтчел буын б-н аерылып тора. Ана Ш.нең корсагы очында чаккычы бар, аның ярдәмендә алар корбанын параличлый һәм дошманнардан саклана. Якынча 23 мең төре билгеле, киң таралганнар, Россиядә якынча 2,5 мең төре бар. Татарстан терр-ясендә *сколияләр* (Scolidea), сапигалар (Sapygoidea), ялтырак Ш. (Chrysidoidea), юл Ш.е (Pampiloidea), бәрхетсыман кырмыскалар (Multiloidea), *җыелма канатлы шөпшәләр* (Vespoidea), *казучы шөпшәләр* (Sphecoidea) һ.б. өссемьялыклар вәкилләре билгеле. Күпчелек Ш. ялгыз яши (ялгыз Ш.), җыелма канатлы Ш. өссемьялыгыннан чын Ш. семьялыгы вәкилләре һәм казучы Ш.нең күп кенә төрләре (җәмгыяви Ш.) гаилә булып яшиләр. Җәмгыяви Ш.нең аеруча зурлары (35–40 *мм*) *төклетуралар* ыругына карый. Бәрхетсыман кырмыскаларның кайбер төрләрендә ана затлары канатсыз. Олы затлар, кагыйдә буларак, чәчәк нектары б-н туеналар. Күпчелек Ш.нең личинкалары ояларда җитлегә, әмма сфецидалар (Sphecidae) семьялыгының якын төрләренең яки хризидидалар (Chrysididae) семьялыгының тугандаш булмаган төрләренең ояларын һәм азык запасларын кулланучы оя паразитлары да бар. Күкәй салыр алдыннан Ш. азык әзерләмиләр (аларның гомуми билгесе). Күкәйдән чыккан личинкаларын, гадәттә, бөҗәк һәм үрмәкүчләр б-н туендыралар. Үсемлекләрне серкәләндереп, урман һәм а.х. корткычларын юк итеп файда китерәләр. Күп кенә Ш.нең чагуы кешедә авырту барлыкка китерә.

*Е.А.Сапаев.*

**ШПА́КОВ** Иван Михайлович (1.1.1906, Казан губ., Цивильск өязе Иске Корбаш а. — 13.1.1988, Казан), инженер-механик, «Радиоприбор» з-ды директоры (1946–60). Казан керәшен пед. техникумын (1925), Казан авиация ин-тын (1935) тәмамлый. 1925–29 елларда ВЛКСМның Мәлки волость ком-ты секретаре, Зур Кайбыч район советы башкарма ком-тының халык мәгарифе буенча инспекторы. 1935–38 дә 124 нче з-дта: мастер, инженер, цех башлыгы урынбасары; 1938 дән 8 нче кино тасмалары з-ды директоры; 1939–41 дә 169 нчы з-д директоры. 1941–46 да 168, 464 нче з-длар директоры (Рязань ш., Мәскәү өлкәсе Долгопрудный ш.). Ш. җитәкчелегендә пластмассалардан детальләр эшләү з-ды (Казан) җирлегендә радиотехник аппаратура җитештерүче эре пр-тие оештырыла. Яңартып техник кораллану уздырыла, берничә яңа цех — механика, корпуслы детальләр, җыю һәм монтажлау, эшләнмәләрне көйләү һәм тапшыру, контроль-сынау цехлары һ.б., социаль-көнкүреш объектлары, тораклар төзелә. Радиолокацион тану-аеру системасы эшләнмәләрен, якын арада навигация һәм җиргә төшерү борт аппаратурасын, ш.у. халык куллануы товарларын («Звезда» телевизорлары һ.б.) җитештерү җайга салына. 1951–59 да ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШПИЛЕ́ВСКИЙ** Сергей Михайлович (8.5.1833, Мәскәү — 21.7.1907, Ярославль ш.), юрист, тарихчы, археолог, нашир, җәмәгать эшлеклесе, дәүләт хокукы д-ры (1870), ышерен советник (1894). Дворяннар нәселеннән. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1856). 1856 елдан К.С.Аксаков һәм А.С.Хомяковның славянофиллар түгәрәкләре б-н хезмәттәшлек итә. 1859 да «Молва» г-тасын (Мәскәү) редакцияли. 1860–66 да Казан ун-тының рус хокук тарихы каф. адъюнкты, 1866–70 тә доценты, 1870–85 тә ординар профессоры, 1873–76 да юридик ф-т деканы. Бер үк вакытта, 1862–85 тә, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында укыта. 1875–79 да Казанның аерым цензоры. 1867–85 тә «Казанские губернские ведомости» г-тасының рәсми булмаган өлеше мөхәррире. «Справочный листок Казани» (1867), «Волжско-Камское слово» (1881–82) г-таларын нәшер итә. 1877–78 дәге рус-төрек сугышы вакытында Казан губернасы терр-ясендә славяннарны азат итү өчен хәйрия акчасы җыюда катнаша. 1877 дә Казанда 4 нче Археол. съездын оештыруда катнаша. Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыятенә (1878) нигез салучыларның берсе: 1884 кә кадәр шул җәмгыять рәисе урынбасары, 1884–85 тә рәисе. Археол. казу эшләре алып бара, матди мәдәният истәлекләрен барлый, Казан төбәге халыкларының хокукый йолаларын өйрәнә. 1885–1904 тә Ярославльдә Демидов юридик лицее директоры һәм рус хокукы тарихы кафедрасының атказ. профессоры. Ш. — Россиядә славянофиллар хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе; рус тарих-хокук мәктәбенең «җәмәгать» («халык») юнәлеше вәкиле. Чагыштырма-тарихи хокук юнәлешендә эшләнгән «Пётр I гә кадәрге дәүләт үсешенә бәйле рус хокукы чыганаклары турында» («Об источниках русского права в связи с развитием государства до Петра I», 1862), «Борынгы славяннарда һәм германнарда кардәшлек яклавы берлеге» («Союз родственной защиты у древних славян и германцев», 1866), «Карамзинның Россия дәүләте тарихы рус хокук тарихына карата мөнәсәбәттә» («История государства Российского Карамзина в отношении к истории русского права», 1866), «Халыкның хокукый йолалары турында» («О народных юридических обычаях», 1867) хезмәтләрендә төп игътибар дәүләт институтларына түгел, җәмгыятьнең көнкүрешенә юнәлтелә. Фәнни эшчәнлегенең икенче юнәлеше — Казан, Идел буе төбәге тарихы. Аның «Казан шәһәренең тарихи истәлекләре күрсәткече» («Указатель исторических достопримечательностей г.Казани», 1873), «Казан губернасының борынгы шәһәрләре һәм башка болгар-татар истәлекләре» («Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии», 1877) монографияләре мөһим тарихи чыганаклар һәм археол. истәлекләр тупланмасы булып торалар. Ш. «Императрица Екатерина II нең Идел буйлап сәяхәте» («Путешествие императрицы Екатерины II по Волге», 1873), «Император Александр I нең Казан турында кайгыртуы» («Заботы императора Александра I о Казани», 1878), «Алексей Михайлович патшалык иткән вакытта Казанда чума авыруы турында» («О чуме в Казани в царствование Алексея Михайловича», 1879) һ.б. хезмәтләр авторы.



С.М.Шпилевский.

Х е з м.: Старые и новые города и борьба между ними в Ростово-Суздальской земле. Ярославль, 1892; Великий князь смоленский и ярославский Фёдор Ростиславич Чёрный. Ярославль, 1899; Столетие Училища имени Демидова. 1803–1903. Ярославль, 1903.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; К а т а н о в Н.Ф. Памяти С.М.Шпилевского // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1907. Т. 23, вып. 4.

*Е.Б.Долгов.*

**ШПИ́ЛЬМАН** Илья Абрамович (29.11.1918, Могилёв губ. Витебск ш. — 2006, Оренбург ш.), геолог-нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950, 1983), геол.-минерал. фән. канд. (1950). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлый (1941). 1946–58 елларда «Татнефтегеолразведка» трестында эшли, эзләү-бораулау конторасы баш геологы (1949 дан). 1958–2001 дә Оренбургның фәнни һәм җитештерү оешмаларында. Эре углеводород чыганакларын — Ромашкино, Яңа Елховой, Оренбург ятмаларын һ.б.ны беренче булып ачучыларның берсе. Ш. яңа тип нефть ятьмәләрен билгели, улеводородларны эзләү һәм разведкалауның яңа методикасын нигезли. Дәүләт бүләге Ромашкино нефть һәм Оренбург газ, нефть конденсат чыганакларын ачу һәм разведкалавы өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШПУ́ЛЕР** Бертольд (5.12.1911, Карлсруэ ш., Германия — 6.3.1990, Гамбург ш., Германия), тарихчы, шәркыятьче галим. Бисмарк исем. гуманитар гимназияне тәмамлый (1930), Гейдельберг (1931–32), Гамбург (1932), Мюнхен (1933), Бреслау (1933–35) ун-тларында укый. 1936–37 елларда Берлин ун-ты каршындагы «Көнчыгыш Европа тарихы еллык басмасы» («Ежегодник истории Восточной Европы») мөхәррире. 1938 дә «Иранда монголлар» («Монголы в Иране») темасы буенча диссертация яклый. Икенче бөтендөнья сугышы елларында армиядә тәрҗемәче буларак хезмәт итә. 1944 тә «Идел-Урал» легионы өчен муллалар мәктәбен җитәкли, шунда ук төрки халыклар тарихы буенча лекцияләр укый. 1945–48 дә Гёттинген, 1948–80 дә Гамбург ун-тларында шәркыять гыйлеме каф. мөдире. Алтын Урда һәм аннан соң формалашкан төрки-татар дәүләтләре тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә. «Идел-Урал. Идел б-н Урал арасындагы халыклар һәм илләр» («Idel-Ural. Volker und Staaten zwischen Wolga und Ural», Berlin, 1941), «Алтын Урда. Монголлар Русьта, 1223–1502» («Die Goldene

Horde. Die Mongolen in Russland, 1223–1502», Leipzig, 1943) хезмәтләре авторы.

Х е з м.: Geschichte der islamischen Länder ein Überblick. Die Mongolenzeit. B., 1948; Geschichte der islamischen Länder. Abschnitt 1. Leiden, 1952.

*Әд.:* Г и л я з о в И.А. На другой стороне: Коллаборационисты из поволжско-приуральских татар в годы Второй мировой войны. К., 1998; Г а т и н М.С. Шпулер Бертольд // Ислам на европейском Востоке: Энцикл. словарь. К., 2004; W e r n e r E. Spuler Bertold // Neue Deutsche Biographie. B., 2010. Bd. 24.

**ШТЕР** Георгий Карлович (30.6.1857, Лифляндия губ. Дерпт ш. — 18.5.1898, Казан), икътисадчы, статист, политэкономия д-ры (1891), статский советник (1894). Дворяннар нәселеннән. Дерпт ун-тын тәмамлый (1880). 1880 елда Халык мәгарифе министрлыгында (С.-Петербург) эшли. 1882–86 да Дерпт уку-укыту округы попечителе канцеляриясе чиновнигы. Казан ун-тының политэкономия һәм стат. каф. экстраординар (1891 дән), ординар (1894 тән) профессоры. Политэкономия мәсьәләре буенча Штирнер һәм Ф.Ницше карашлары тарафдары. «Статистик ысул турында берничә сүз» («Несколько слов о статистическом методе». СПб., 1897), «Кыскача статистика курсы» («Краткий курс статистики», ч. 1–2, 1898–1900) хезмәтләре стат. теориясе һәм тарихына багышлана, ш.у. рус артеле тарихы турында хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Ueber Ursprung, Geschichte, Wisen und Bedentung des russischen Artels. Ein Beitrag zur Kultur — und Wirtschaftsgeschichte des russischen Volkes: В 2 ч. Дерпт, 1890–91.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**ШТЕРӘ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 17 *км* көньяктарак, Щира елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 345 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Иштера, Щира Татарская, По речке Ищерке исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н көн күрә. 20 йөз башында ашлык саклау-сату һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 835 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1924 тән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 50 ир-ат; 1859 да — 386, 1897 дә — 612, 1908 дә — 735, 1920 дә — 784, 1926 да — 779, 1938 дә — 940, 1949 да — 895, 1958 дә — 634, 1970 тә — 599, 1979 да — 464, 1989 да — 377, 2002 дә — 349 кеше.

**ШТИ́ЛЬМАН** Фроим Львович (14.10. 1912, хәзер Украина Респ-касының Киев өлкәсе Бориспольский р-ны Старое а. — 1976), инженер-металлург, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). Киев индустриаль ин-тын тәмамлый (1938). 1941–69 елларда Яшел Үзән суднолар төзү з-дында: мастер, корыч коючехының техник бюро башлыгы, өлкән инженер, баш металлург (1953 тән). Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге коеп ясалган аеруча чыдам якорь чылбырларын агымлы җитештерүне оештырганы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШТОРМ** (голл. storm), давыл, озакка сузылган, тизлеге 20 *м/с* һәм аннан артып киткән бик көчле җил (Бофорт шкаласы буенча 9 баллы). Коры җирдә җимерелүләр һәм диңгездә көчле дулкыннар барлыкка китерә. Тизлеге 30 *м/с* тан артып киткәндә — ураган, кыска вакытка җилнең тизлеге 20–30 *м/с* тан артса шквал дип йөртелә. Гадәттә, *циклоннар* узган вакытта күзәтелә. ТРда елның суык вакытында күбрәк өстенлек итүче җилләр юнәлешендәге елга үзәннәрендә, елның җылы вакытында сирәгрәк явым-төшемнәр (яшенле шкваллар, өермәләр), ш.у. алардан башка (тузан өермәләре) гына кисәк барлыкка килүче барик үзгәрешләр туганда билгеләнә. Давыллы өермә (ураган) билгеле бер урында гына барлыкка килә, каралты-кураларның җимерелүенә, электрүткәргеч линияләрнең өзелүенә, урманнарда агачларның авуына, сынуына китерә (мәс., 2000 елның 19 июнендә Яшел Үзән р-нында, 2007 нең 8 июлендә Казан тирәсендә күзәтелә). Куйбышев сусаклагычында май аенда (3–11 тапкыр) һәм җәйге чорда (7–23 тапкыр) 7–8 баллы (җилнең тизлеге 13 *м/с* һәм аннан артык) дулкыннар, көзен (13–26 тапкыр) аеруча көчле һәм озакка сузылган Ш.нар була. Җилнең тизлеге 30–35 *м/с* булган (40 *м/с* ка кадәр үзгәрүче) Ш. 1973 нең 19–21 октябрендә билгеләнә, дулкыннарның биеклеге 2–2,5 *м* га җитә. Сусаклагычта озакка сузылган Ш. октябрьдә ел саен, ә көзнең калган айларында 2 елга бер тапкыр күзәтелә.

*Әд.:* Климат Татарской АССР. К., 1983.

*Э.П.Наумов.*

**ШТУКЕНБЕ́РГ** Александр Антонович (7.11.1844, Тверь губ. Вышний Волочёк ш. — 31.3.1905, Казан), геолог, географ, палеонтолог, археолог, коллекционер, минералогия һәм геогнозия д-ры (1875). Казан геол. мәктәбен нигезләүче. Петербург ун-тын тәмамлаганнан соң (1867), шунда ук эшли. 1873 елдан Казан ун-тының геол. каф. мөдире, ординар проф. (1876). Бер үк вакытта, 1896–1904 тә, Казан вет. ин-тында укыта. Табигыятьчеләр җәмгыяте вице-президенты (1874 тән), президенты (1880 нән); Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыяте әгъза-оештыручысы (1878), шәрәфле әгъзасы (1903); Казан шәһәр музее советы башлыгы (1896–1905); Казанда һәм Түбән Новгородта фәнни-сәнәгый күргәзмәләр оештыруда башлап йөрүче (1896). Археол. тикшеренүләрнең палео-этнологик юнәлешенә нигез сала, казылма фаунаның дистәләрчә яңа төрләрен ачыклый, Пермь системасының Көңгер ярусын аерып чыгара (1890), Казан губернасының беренче геол. тасвирламасын төзи, Казанның җир асты суларын фундаменталь рәвештә өйрәнә (бу шәһәрне су б-н тәэмин итүдә зур роль уйный), ун-тның Геол. музеен (2003 тән Ш. исемендә) оештыруга җитди өлеш кертә, Казанның төбәкне өйрәнү музеен төзүдә катнаша (табигый тарих бүлеге директоры), археол. эшләрдә типология алымын гамәлгә кертә, Россия археологиясендә беренче булып элгәреге металл дәверенә караган бакыр һәм бронза эш коралларының классификациясен төзи (1901), таш һәм бронза гасырларга нисбәтле Атабай, Карташиха, Яңа Мукшы һ.б. торулыкларда, Ананьино каберлегендә, Идел буе Болгар дәүләтенең шәһәрлекләре терр-яләрендә һ.б.да археол. тикшеренүләр һәм казу эшләре уздыра. Хезмәтләре Идел-Урал төбәгенең һәм Европаның төньяк-көнчыгыш өлешенең югары палеозой дәверенең һәм иң яңа геол. тарихының геологиясенә, палеонтологиясенә, Көнчыгыш Европаның һәм Скандинавиянең палеогеографиясенә һәм палеоклиматологиясенә, таш һәм бронза гасырларның, Идел Буе Болгар дәүләтенең гидрогеологиясенә, археологиясенә карый.



А.А.Штукенберг.

Х е з м.: Материалы для изучения каменного века в Казанской губернии // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Имп. Казан. ун-те. 1885. Т. 14, вып. 5 (автордаш); Материалы для изучения медного (бронзового) века восточной полосы Европейской России // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии. 1901. Т. 17, вып. 4; Краткий курс палеонтологии (палеозоология). К., 1902.

*Әд.:* С о к о л о в Б.С. Александр Антонович Штукенберг (1844–1905). К., 2003.

*С.В.Кузьминых.*

**ШТУ́ЦЕР** Иван Иванович (1882, Мәскәү — 1932, Алма-Ата), агроном. Германиядә белем ала (Галле ш.). 1911–20 елларда Казан губернасы а.х. ведомствосында эшли. 1920–30 да Казан а.х. тәҗрибә станциясенең селекция бүлегендә җитәкче, бер үк вакытта ТАССР Игенчелек халык комис-тының орлыкчылык бүлеге башлыгы. Н.И.Вавилов, А.В.Чаянов, Н.Д.Кондратьев эшен дәвам итә. 1920–26 да Татарстанның һәр агротуфраклы районы өчен культуралар буенча чагыштырма таблицалар һәм карталар төзи. Хезмәтләре крәстиян хуҗалыклары икътисады, базар мөнәсәбәтләре, орлыкчылык һәм кооперация мәсьәләләренә карый. Көзге арыш, бодай селекциясе б-н шөгыльләнә. Тарының «*Казан 506*» сорты авторы. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Восстановление сельского хозяйства Татреспублики и перспективы на будущее // Труд и хозяйство. 1924. № 12; Пути к поднятию производительности полеводства в Татреспублике // Труд и хозяйство. 1925. № 1; К вопросу о расслоении крестьянства в Татреспублике // Труд и хозяйство. 1926. № 4; Материалы по вопросам об оскуднении сельского хозяйства Татреспублики. К., 1928.

*Р.Ә.Әсретдинова.*

**ШТЫ́РКИНА** Софья Әхмәт кызы (15.7.1912, Самара губ. Сорочинск а., хәзер Оренбург өлкәсе Сорочинск ш. — 2.3.2002, Казан), икътисадчы, СССР Дәүләт банкының Татарстан

респ-ка конторасы идарәчесе (1965–76). Самара финанс-икътисад техникумын (1932), Казан финанс-икътисад ин-тын (1949) тәмамлый. 1932–76 елларда СССР Дәүләт банкының Татарстан респ-ка конторасында эшли: икътисадчы, бүлек башлыгы (1941 дән), контора идарәчесе урынбасары (1960–65). Респ-ка халык хуҗалыгында финанс дисциплинасын, акча әйләнешен ныгытуга, кредит ресурсларының нәтиҗәлелеген һәм аларны файдалану күләмен үстерүгә зур өлеш кертә. 1967–71 дә ТАССР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ШТЫРКО́В** Евгений Иванович (22.12.1936, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1985), проф. (1991), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1994, 2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), Гамәли оптика ин-тында эшли, квант электроникасы лаб-ясе башлыгы (1966 елдан). 1971 дән РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, нәсызыкча лазерлы спектроскопия лаб-ясе мөдире (1989 дан), баш фәнни хезмәткәр (1993 тән). Хезмәтләре квант электроникасына, голографиягә, нәсызыкча оптикага карый. Ш. резонанслы динамик голографиянең физик нигезләрен эшли (СССР Дәүләт бүләге, 1982). Яктылыктан индукцияләнгән фәзаи рәшәткәләрнең вакыт эчендә таратылган яктылык кырларында генерациясе күренешен алдан әйтеп, соңыннан ачыклый. 1973 тә лазер ярдәмендә кыздырып йомшарту күренеше ачылуга китергән тикшеренүләрдә катнаша (СССР Дәүләт бүләге, 1988). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Рассеяние света на периодической структуре из возбуждённых и невозбуждённых атомов // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1970. Т. 12; Локальный лазерный отжиг ионнолегированных полупроводниковых слоёв // Физика и техника полупроводников. 1975. Т. 9 (автордаш); Отображающие свойства динамических эхо-голограмм // Оптика и спектроскопия. 1976. Т. 40 (автордаш); Индуцированная решётка, формируемая в рубине интерференцией атомных состояний // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1978. Т. 27 (автордаш).

**ШУБА́Н** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шушма елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,4 *км*. Бассейнының мәйданы 34,6 $км^2$. Елга башы Арча р-ны Кызыл Игенче авылыннан 2,5 *км* көнчыгыштарак урман массивында, тамагы Балтач р-ны Түбән Шубан авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 172 *м*, тамагыныкы — 96 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Ш.ның 1,6 шар *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 126 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 115 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,015 $м^3/с$. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 0,54 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШУ́БИН** Борис Андреевич (23.12.1937, Чистай р-ны Приютовка а. — 7.9.2005, Казан), рәссам-керәч сәнгате остасы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1982). Абрамцево сәнгать-сәнәгать уч-щесен тәмамлый (1963). Декоратив-гамәли сәнгатьтә әйдәп баручы рәссамнарның берсе, Татарстанда көнкүреш нәфис керәче яңарышы һәм аны күпләп җитештерүнең башында тора. Казан төзелеш материаллары комб-тында керәч цехын оештыручы (1964), цех башлыгы (1995). Ш., кою технологиясен кулланып, әйберләрне серияләп эшләү ысулын (милли ашлар өчен савыт-саба, сервизлар, бизәкле вазалар, тәлинкәләр һ.б., 700 дән артык әйбер төрләре), яңа оригиналь калыплар эшли, сәнгатьчә бизәү ысулларын: контррельеф, ябыштыру, бизәү, төсле чынаяк, люстр, ангоб, кобальт, эмаль һ.б.ны үзләштерә. Әсәрләрен терракота, шамот, фаянс, фарфор, майоликадан ясый. Ш.ның күп авторлык эшләнмәләре 3 млн. һәм аннан да артыграк данәдә тиражлана. Күргәзмә керамикасы сәнгатен (кече скульптура, идән вазалары, дивар тәлинкәләре һәм



Б.А.Шубин.

орнаментлы панно) үстерүгә зур өлеш кертә. Әсәрләрнең тематикасын һәм үрнәкләрен сайлаганда татар фольклорына, татар орнаменты үрнәкләрен стильләштерүгә мөрәҗәгать итә, халык сәнгатенә хас төсләр файдалана. Болгар, Алтын Урда һәм Казан татарлары керәче бизәге һәм калыпларын яңарта, *Питрәч чүлмәк ясау кәсепчелеге* традицияләрен үзләштерә.

Төп әсәрләре: пәрәмәч (1966), шәраб (1967), буза (1968), әйрән (1975) өчен, «Авыл мотивлары» (1995) савыт-саба җыелмалары; кош теле өчен савыт (1969), «Тур» кувшины, квас өчен (икесе дә — 1980); «Атлар» (1984), «Керәчнең тууы» (1989) бизәкле вазалары; «Юбилейга» (1979), «Алтын бакча» (1991) идән вазалары; «Сабан туе» (1967), «Абыстай» (1969), «Казан гербы» (1991) дивар тәлинкәләре; «Казан» штофы (1975); «Бәхет кошы» (1981), «Төрки яугир-аучылары» (1981) паннолары; «Алтынчәч» (1965), «Ай кызы» (1966), «Карәхмәт» (1978), «Сабан туена бару» (1984) кече скульптуралары һ.б.

1964 тән респ-ка — 1 нче (1983), 2 нче (1985), 3 нче (1989) респ-ка декоратив-гамәли (барысы да Казанда), «Совет Татарстанына 60 ел» (1980, Мәскәү, Казан), «Керәч дөньясы» (2001, Казан); төбәкара — «Зур Идел» (1964, 1967, 1969), «16 автономияле республика» (1971, Мәскәү) күргәзмәләрендә, халыкара күргәзмә-ярминкәдә (1980, Лейпциг ш., ГДР) һ.б.да катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1969, 1976, 1988 һ.б. Казанда, 1983 тә Мәскәүдә уздырыла.

Әсәрләре «Кусково утары» Дәүләт керәч музеенда, ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә һ.б.да саклана.

Ш. турында Казан телевидение студиясендә «Керәч тылсымчысы» (1969), «Татар сувенирлары» (1977) телефильмнары төшерелә.

*Әд.:* Радуга в доме: Фотоальбом. К., 1985; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. По мотивам бул-









Б.А.Ш у б и н. 1. «Тимер» дивар тәлинкәсе. Балчык. Контррельеф, төсле ялтыравык. 1968; 2. «Сөембикә». Терракота. Уеплау. 1975; 3. Ширбәт өчен «Шәрекъ» савыт-сабасы. Фаянс. Ялтыравыклы бизәк. 1981. 2-3 – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда; 4. Шулпа өчен савыт-саба җыелмасы. Терракота. Контррельеф, төсле ялтыравык, эмаль. 1970. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

гарской керамики // Декоративное искусство СССР. 1986. № 11; шул ук. Художник Борис Шубин. Искусство керамики Татарстана. К., 1999.
*Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова.*

**ШУ́БИН** Владимир Николаевич (8.11.1898, Вятка губ., хәзер Киров өлкәсенең Нолинск ш. — 1.8.1987, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1946), проф. (1946). Пермь мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1922), Коми-Пермяк милли округының Юрлу авылында эшли. 1922 елдан Пермь ун-тының госпиталь хирургиясе клиникасында. 1936 дан Ижевск мед. ин-тының гомуми хирургия кафедрасында. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1941–44 тә Казанда — ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-тының 1311 нче эвакогоспиталендә әйдәп баручы хирург. 1944–50 дә Әстерхан мед. ин-тының гомуми хирургия каф. мөдире. 1950–70 тә Казан мед. ин-тында, гомуми хирургия каф. мөдире, бер үк вакытта, 1952–68 дә, проректор, 1971 дән проф.-консультант. Хезмәтләре корсак куышлыгы хирургиясенә, сирәк очрый торган хирургик авыруларны дәвалауга карый. Ш. сепсис очрагында ботның югары эпифазы резекциясе ысулын эшли. Тегәр алдыннан эчәклек яраларын эшкәртүнең яңа ысулы, Пирогов операциясе модификациясе, корсак стенасындагы зур тишемле бүсергә операция ясау авторы. Ленин ордены, медальләр, РСФСР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: До- и послеоперационный период. К., 1965; Редкие хирургические болезни. К., 1969.

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**ШУ́БИНА** Людмила Егоровна (9.10.1948, Казан) спортчы, тренер (гандбол), СССРның атказ. спорт остасы (1976), Әзәрбайҗан Респ-касының атказ. тренеры (2008). Әзәрбайҗан физик культура ин-тын тәмамлый(1977). «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан), тренеры — Р.М.*Яушев*. 1964–67 елларда «Электрон» (Казан), 1967–69 да «Калининец» (Свердловск ш.), 1968–88 дә «Спартак» (Баку ш.) командаларында, бер үк вакытта СССР җыелма командасы (1970–76) составында уйный. СССР (1970–77 — көмеш, 1969, 1980, 1982, 1984 — бронза), дөнья (1973 — бронза, 1975 — көмеш) чемпионатларында, СССР халыклары спартакиададаларында (1971 — көмеш, 1975, 1979 — бронза) катнаша; Гандбол федерациясенең Европа кубогы ярышларында (1983), Олимпия уеннарында (1976) җиңүче. 1977 дән балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (1977–90), Әзәрбайҗан хатын-кызлар (1991–96), Кувейт (1996–99) җыелма командаларында, «Гарадаг-Цемент-Спартак» командасында (Баку; 2001 дән) тренерлык эшендә. 2007 дән «Гарадагцемент» гандбол клубы президенты. Әзәрбайҗан Респ-касының «Шөһрәт» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**ШУ́БИНА** (Клюева) Мария Тимофеевна (8.5.1930, Мордва АССРның Ичалки р-ны Протасово а.), спортчы (байдаркаларда һәм каноэда ишү), СССРның атказ. спорт остасы (1960); спорт табибе, мед. фән. канд. (1975). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1956). «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан). Олимпия уеннарында (1960, к-2, 50 *м*), дөнья (1958, к-2, 50 *м*; 1963, к-1, 50 *м*, к-4, 50 *м*; 1966, к-4, 50 *м*), Европа (1963, к-1, 50 *м*; 1965, к-2, 50 *м*, к-4, 50 *м*; 1967, к-4, 50 *м*), СССР (1959–60, 1962–63, 1965, 1967), ТАССР (1954–55, төрле экипажлар составында) чемпионатларында җиңүче. Дөнья (1963,1966, к-2, 50 *м*), Европа (1959, 1963, к-2, 50 *м*) чемпионатларында көмеш медаль ала. 1946–50 елларда район хастаханәсендә фельдшер (Ичалки р-нының Кемля пос.), 1956–64 тә сәнәгать санитария табибе (Владивосток ш.), 1964 тән спорт табибе (Волгоград ш.). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

**ШУВА́ЕВ** Александр Иванович (22.11.1927, хәзер Алтай краеның Курьинский р-ны Кузнецовка а. — 23.5.2003, Чаллы ш.), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984), РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1980). Алтай политехник ин-тын тәмамлый (1950, Барнаул ш.). 1942–72 елларда Алтай трактор з-дында эшли: мастер, өлкән мастер, баш технолог урынбасары, техник контроль бүлеге башлыгы, баш технолог. 1972–86 да «КамАЗ» ҖБдә: баш инженер урынбасары, баш технолог, берләшмәнең ген. директоры урынбасары (1982 дән). 1986–89 да «Алабуга җиңел автомобильләр заводы» ҖБдә: ген. директорның беренче урынбасары, ген. директор (1987 дән). Дәүләт бүләге басым б-н вал һәм кучәрләрнең төгәл салкын формаларын барлыкка китерү өчен яңа алымнар һәм автоматлаштырылган җиһазлар комплексын булдыруда һәм машина төзелешенә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Сорокин Н. Завод XXI века // Над шишкинским бором рассвет. К., 1989; Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.
*Б.А.Канеев.*

**ШУГА́Н** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 16,5 *км*. Бассейнының мәйданы 82,9 *км*². Елга башы Азнакай р-ны Татар Шуганы авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Мөслим р-ны Рус Шуганы авылыннан 1 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 76 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Ш.ның 1,2 һәм 4,1 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,26 *км/км*². Ш.ның 1,2 һәм 4,1 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,26 *км/км*². Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәенлек саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 121 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 65 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,016 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Ш. бассейнында суының гомуми күләме 1,94 млн. *м*³ булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШУГА́Н** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шуган елгасы буенда. 2010 елда 420 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 80%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1930 елларда «Овцевод» с-зы бүлекчәсе буларак нигез салына. Оешкан көненнән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1938 дә — 1624, 1949 да — 1721, 1958 дә — 883, 1970 тә — 915, 1979 да — 772, 1989 да — 505, 2002 дә — 470 кеше.

**ШУ́ЙСКИЙ** Пётр Иванович (1515 тирәсе — 26.1.1564, Чашники ш., хәзер Беларусь Респ-касының Витебск өлкәсендә), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, кенәз, бояр (1550). 1545–51 еллардагы *Казанга Рус дәүләте яуларында* катнаша; 1547 дә һәм 1550 дә алгы полкның 1 нче воеводасы. А.Б.*Горбатый-Шуйский* б-н бергә Зөя шәһәренә нигез сала, 1551–53 тә анда воевода булып тора. 1553–57 дә Казанның 1 нче воеводасы. Элекке Казан ханлыгы халкының кораллы күтәрелешен бастыру б-н җитәкчелек итә (к. *Казан җирләрендә азатлык сугышлары, 1552–56*). Казан җирләрен архиерей йортына, монастырьларга, дворяннарга, йомышлы татарларга өләшүне оештыра (1557). Ливон сугышында (1558–83) катнаша; Полоцк шәһәренә яу б-н барганда (1563) зур полкның 1 нче воеводасы. 1564 нең 26 гыйнварында Чашники янындагы сугышта поляклар яисә җирле крәстияннәр тарафыннан үтерелә.

*Әд.:* Абрамович Г.В. Князья Шуйские и российский трон. Л., 1991.

**ШУКРАЛИ́НКА** елгасы, к. *Чаллы*.

**ШУЛА́ЕВА** Марина Петровна (13.7.1966, Яшел Үзән ш.), микробиолог, биол. фән. канд. (2009), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1915). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1990), А.Е.Арбузов исем. органик һәм физик химия ин-тында өлкән лаборант булып эшли, 1995 елдан Казан мед. академиясенең микробиол. кафедрасында. Фәнни эшчәнлегенең төп юнәлеше кабат синтезлашкан химик кушылмаларның микробларга каршы активлыгын өйрәнүгә карый, махсус курслар алып бара. Уку әсбаплары авторы, уйлап табуга 7 патенты бар. Дәүләт бүләге «Физиологик актив матдәләрнең биомиметик караш нигезендә медицина һәм ветеринария өчен юнәлешле синтезы» хезмәтләр циклы өчен бирелә.

Хезм.: Синтез, структура и антимикробная активность продуктов реакций хлорнитрозамещенных бензофуразанов и -фуроксанов с морфолином // Журнал общей химии. 2017. Т. 87. Вып. 12 (автордаш); Детекция β-лактамаз AmpC у клинических изолятов энтеробактерий // Практическая медицина. 2018. № 1 (112) (автордаш); Chiral S-stannyl dithiophosphates and dithiophosphonates on the basis of monoterpenols // Applied Organometallic Chemistry. 2018. Т. 32. № 5 (автордаш).

**ШУЛИКО́ВСКИЙ** Валентин Иванович (29.6.1922, Новосибирск ш. — 7.12.1973, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1965), проф. (1967). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1948), шунда ук эшли: физика һәм механика-матем. ф-тлары деканы (1968–69; 1969–73), чагыштырмалылык теориясе һәм гравитация, геом. кафедралары профессоры (1967–69; 1969 дан). 1965–67 дә София, Пловдив (Болгария) югары уку йортларында укыта. Хезмәтләре Риман геометриясенә һәм аффин бәйлелекле фәзалар геометриясенә карый. Ш. аффин бәйлелегенең ике үлчәнешле фәза челтәрләре теориясен системалаштыра һәм алга таба үстерә, челтәрләр теориясе аппаратын классик дифференциаль геометрияне бәян итүдә куллана. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Классическая дифференциальная геометрия в тензорном изложении. М., 1963; Проективная теория сетей. К., 1964; Дифференциална геометрия. Пловдив, 1967.

*Әд.:* Механико-математический факультет Казанского университета: Очерки истории. К., 2003; Валентин Иванович Шуликовский (к 60-летию со дня рождения) // Тр. геометр. семинара. 1982. Вып. 14. *В.В.Шурыгин.*

**ШУЛПИ́НОВ** Сергей Семёнович (15.10.1881, Тверь губ., Весьегонск ш. — 1959, Казан), гигиенист, мед. фән. д-ры (1950), проф. (1950). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1911), Байкал арьягында сан. табибе булып эшли, 1924 елдан Казан шәһәр сәламәтлек саклау бүлегендә. 1926 дан Казан ун-тының мед. ф-тында (1930 дан Казан мед. ин-ты), 1950–56 да коммуналь гигиена каф. мөдире. Хезмәтләре яшәү тирәлеге гигиенасына һәм пр-тиеләрдә, ш.и. Казан һәм Кукмара аяк киеме ф-каларында киез итек җитештерүчедә эшләүчеләрнең хезмәт шартларын, эш урыннарының яктыртылышын бәяләүгә, эндемик зоб этиологиясе һәм авыруны кисәтү мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сравнение разных приборов для исследования освещённости // Вестн. Казан. ин-та научн. организации труда. 1929. № 3; Содержание растворённого кислорода в воде р. Волга // Труды КГМИ. 1950. Т. 1, № 6.

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**ШУЛУ́ТКО** Лазарь Ильич (24.6.1897, Севастополь ш. — 2.12.1971, Казан), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1940), проф. (1940), ТАССРның, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1945, 1970), РСФСРның атказ. табибе (1940). Проф. М.О.Фридланд шәкерте. Одесса ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1922), Севастополь, Харьков, Духовщина (Смоленск өлкәсе), Евпатория шәһәрләренең мед. учреждениеләрендә эшли. 1932–71 елларда Казан ГИДУВында, травматология һәм ортопедия каф. мөдире (1937 дән). Бер үк вакытта, 1945–60 та, Казан Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тының оештыручысы һәм директоры. Бөек Ватан сугышы елларында ТАССР госпитальләренең баш хирургы. Хезмәтләре төрле җәрәхәтләргә: ачык һәм ябык сөяк сынуларга, сөяк тукымасы шешләренә, сколиозга һ.б.га диагноз куюга һәм авыруларны дәвалауга карый. Россиядә диагноз кую өчен «Шулутко тугымы» кулланыла. Гипертрофик ялган буыннар очрагында кыйпылчыкларга сөяк-сөяк өслеге декортикациясен тәкъдим итә. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Казанда элек Травматология һәм ортопедия ин-ты урнашкан бинага мемориаль такта куелган.

Х е з м.: Диагностическая ценность фистулографии в клинике травм военного времени. К., 1943 (автордаш); Вопросы клинико-рентгенологической диагностики закрытых переломов костей. К., 1965 (автордаш); Боковые искривления позвоночника у детей (сколиоз). К., 1968.

*Әд.:* Л а т ы п о в А.Л. Шулутко Лазарь Ильич // Казан. мед. журн. 1997. № 2.

**ШУЛЬГИ́Н** Борис Владимирович (1.9.1905, Казан — 1.11.1962, Киев), генерал-лейтенант (1954), Сов. Союзы Герое (6.4.1945). БҮБК исем. Мәскәү хәрби мәктәбен (1929), М.В.Фрунзе исем. Хәрби акад. каршындагы офицерлар составының белемен күтәрү курсларын (1948), Ген. штаб Хәрби академиясе каршындагы акад. курсларын (Мәскәү, 1954) тәмамлый. 1926 елдан Кызыл Армиядә. Бөек Ватан сугышында танк полкы командиры, 1943 тән гв. танк бригадасы командиры, Мәскәү, Сталинград янындагы, Курск дугасындагы сугышларда, Белоруссия һәм Польшаны азат итүдә катнаша. Сугыштан соң СССР Кораллы Көчләренең танк гаскәрләрендә җитәкче вазифаларны башкара: 1954–60 та Киев хәрби округы гаскәрләре командующие урынбасары. Өч Ленин ордены, биш Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Кутузов, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казанның бер урамы Ш. исемен йөртә.

*Ф.Г.Миңнеханов.*



Б.В.Шульгин.

**ШУЛЬГИ́Н** Никанор Михайлович (? — 1614), *«Болгавыр заман»* эшлеклесе. 1607–13 елларда Казан дьягы. Воевода В.П.Морозов отряды б-н беренче рус ополчениесенә кушылып киткәннән соң (1611), фактта Казан хакиме булып кала. 1613 тә земство хөкүмәте (1611 дә оештырыла) таләбе буенча Казан дворяннары, стрелецлар һәм йомышлы татарлардан торган отряд б-н Мәскәүгә чыгып китә, ләкин Арзамастан кире борыла. Зөядә Казан дворяннары аны кулга ала. «Яңа елъязмачы»да («Новый летописец») бирелгән рәсми версия буенча, Ш. хыянәт кылуда, кешеләрне Казан воеводасы Б.Я.Бельскийны (1611) үтерергә котыртуда, Казанны Россия дәүләтеннән аеруны планлаштыруда, К.Минин б-н Д.М.Пожарский җитәкчелегендәге ополчениегә ярдәм итүне тоткарлауда гаепләнә, ләкин чынлыкта аның бары тик яңа сайланган патша Михаил Фёдоровичка ант итүдән баш тартуы гына төгәл мәгълүм. Ш. Себергә сөрелә һәм шунда үлә.

*Е.В.Липаков.*

**ШУЛЬГИ́Н** Николай Захарович (14.10.1855, Кавказ өлкәсенең Пятигорск ш. — 15.1.1937, АКШ, Пало-Альто ш.), юрист, сенатор (1911), яшерен советник (1911). Дворяннар нәселеннән. Петербург ун-тын тәмамлый (1880). 1879–82 елларда Петербургта мәхкәмә эшләре хезмәткәре, 1882–83 тә Киев округ мәхкәмәләре секретаре, 1883–85 тә Сенат обер-прокуроры карамагында. 1885–90 да Казан округ мәхкәмәсе прокуроры урынбасары, 1892–97 дә прокуроры. 1897–1905 тә Казан мәхкәмә палатасы прокуроры урынбасары. 1890–92 дә Пермь округ мәхкәмәсе прокуроры. 1905–10 да Сенат обер-прокуроры урынбасары. 1910–11 дә Вильно мәхкәмә палатасы прокуроры. 1911–17 дә Сенатның җинаять эшләре кассация департаментында. 1912–13 тә Россия МС рәисе П.А.Столыпинны үтерү буенча тикшерү эшләре алып бара. 1918 дә Чех-словак корпусы һәм КОМУЧ Халык армиясе Казанны алганда Ш. шунда була, соңыннан Себергә кача. 1918 нең ноябрендә Бөтенроссия хөкүмәте (директориясе) каршындагы юридик киңәшмә әгъзасы. 1919 дан — Япониядә, 1923 тән АКШта яши.

*Әд.:* М у р з а н о в Н.А. Словарь русских сенаторов. 1711–1917 гг.: Материалы для биографий. СПб., 2011. *Е.Б.Долгов.*

**ШУ́ЛЬМАН** Хаим Моисеевич (6.12.1929, Чиләбе өлкәсенең Троицк ш. — 7.1.1998, Казан), нейрохирург, мед. фән. д-ры (1981), проф. (1984), ТАССРның атказ. табибе (1980). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Ленинград нейрохирургия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1957 елдан Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында (нейрохирургия бүлеге). 1966 дан 15 нче шәһәр хастаханәсенең нейрохирургия бүлеге мөдире, бер үк вакытта Казан мед. ин-тының нерв авырулары кафедрасында, 1968 дән травматология, ортопедия һәм хәрби-кыр хирургиясе кафедрасында, 1982 дән нейрохирургия каф. мөдире, 1987 дән неврология, нейрохирургия һәм мед. генетикасы каф. профессоры. Хезмәтләре нерв системасының вертеброген патологиясенә карый. Ш. нейрохирургик операция ысулларын эшли (умырткара дискларны полимер материаллар кулланып протезлауны тәкъдим итә). ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш нейрохирургы һәм төбәкара нейрохирургия үзәге җитәкчесе (1983 тән).

Х е з м.: Клинико-хирургические параллели при остеохондрозе поясничного отдела позвоночника, осложнённом задними грыжами дисков // Журн. невропатологии и психиатрии им. С.С.Корсакова. 1974. № 4; Хирургическое лечение компрессионных форм остеохондроза поясничного отдела позвоночника с протезированием межпозвонковых дисков. К., 1980.

*Әд.:* Профессор Хаим Моисеевич Шульман // Казан. мед. журн. 1998. № 3.

**ШУМА́Н** елгасы, к. *Кырлай.*

**ШУМА́Н** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 25 *км* төньяктарак, Шуман елгасы буенда. 2010 елда 191 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 69%, татарлар — 30%) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек. Урта мәктәп, клуб. 1565 — 67 дән Шумани исемле татар авылы буларак билгеле, 17 йөз башында халкы йомышлылар һәм ясаклы яңа чукындырылганнардан тора. 17 йөз уртасына авылда яшәүчеләр калмый, авыл акрынлап рус алпавытлары (алар арасында М.Н.*Кудрявцев* (18 йөз), Боратынскийлар (19 йөз) була) милкенә күчә. Җирле халык игенчелек, терлекчелек, он тарту, арба ясау, күн эшкәртү, тукыма туку, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1900 дә ачыла), 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1059,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССР ның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 108 ир-ат; 1859 да — 412, 1897 дә — 489, 1908 дә — 567, 1920 дә — 437, 1926 да — 505, 1938 дә — 446, 1949 да — 266, 1958 дә — 209, 1970 тә — 178, 1989 да — 187, 2002 дә — 190 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ШУМКО́ВА** Мария Николаевна (12.2.1909, Оренбург ш. — 16.8. 1989, Казан), агроном, а.х. фән. канд.(1968), РСФСРның атказ. агрономы (1970). Оренбург ит терлекчелеге һәм ветеринария ин-тын тәмамлаганнан соң (1932), Алексеев р-нында — «Татмаслотрест»та, «Свияжский», «Алексеевский» с-зларында эшли. 1934–40, 1946–73 елларда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында. 1940–42 дә Казан а.х. ин-тында. 1942–46 да Казан тимер юлының 1 нче с-зында. Тарының «Казан 61», «Кама» сортлары һәм тары селекциясендә катлаулы гибрид популяция булдыру алымы авторларының берсе. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШУМКО́ВО** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 18 *км* төньяктарак, Екатерина елгасы буенда. 2010 елда 284 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 53%, руслар — 46%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1565–67 дән алпавыт Нелюб Шумков җирендәге Козембердеева авылы буларак билгеле, 17 йөз уртасында сарай (1797 дән — удел) авылы булып китә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Вознесенский исеме б-н дә телгә алына. Халкы игенчелек, терлекчелек, такта яру, балта эше, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Вознесение чиркәве (1874 — 80 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1876 да ачыла), 2 су һәм 5 җил тегермәне, 3 сыраханә, казна шәраб һәм 8 бакалея кибете була; Аеклык җәмгыяте уку залы эшли; Вознесение көнендә ярминкә уздырыла. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4094,96 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Анатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 336 ир-ат; 1859 да — 1639, 1897 дә — 1796, 1908 дә — 1902, 1920 дә — 1756, 1926 да — 1632, 1938 дә — 1041, 1949 да — 914, 1958 дә — 722, 1970 тә — 469, 1989 да — 440, 2002 дә — 408 кеше.

**ШУМЫ́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының сул кушылдыгы. Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Озынлыгы 18,8 *км*. Бассейнының мәйданы 108,1 $км^2$. Елга башы Шумыш авылыннан 5 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Әгерҗе – Акбаш линиясенең 118 нче *км* тимер юл станциясеннән 2 *км* көньяктарак, Зәй сусаклагычы сулары аерылу зонасында. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 72 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Ш.ның 6 кушылдыгы бар, иң зурысы — Чыбыклы (11,1 *км*) — сул кушылдык. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 $км/км^2$. Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 106 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,096 $м^3/с$. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Елгада суының гомуми күләме 0,3 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШУМЫ́Ш** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 22 *км* көньяктарак, Шумыш елгасы буенда. 2010 елда 3 кеше (руслар) яши. 18 — 19 йөзләрдә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә; җирбиләүче И.М.Крыжановскийга эшкә яллана. 20 йөз башында Ш.та тегермән, ашлык саклау-сату һәм 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1086 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 269, 1906 да — 469, 1913 тә — 585, 1920 дә — 594, 1926 да — 519, 1938 дә — 486, 1949 дагы — 373, 1958 дә — 244, 1970 тә — 118, 1979 да — 21, 1989 да — 22, 2002 дә — 2 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ШУНА́К** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 36 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Ирнә елгасы буенда. 2010 елда 35 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, мичкә ясау һәм агач эше б-н шөгыльләнә. 1773 — 75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында земство уч-щесе, ашлык саклау-сату һәм шәраб кибете, тимерче алачыгы, ат, май з-ды, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 410 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Спас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Сарман, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1834 тә — 526, 1859 да — 419, 1884 тә — 612, 1906 да — 412, 1913 тә — 364, 1920 дә — 530, 1926 да — 518, 1938 дә — 582, 1949 да — 440, 1958 дә — 296, 1970 тә — 194, 1979 да — 117, 1989 да — 60, 2002 дә — 44 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ШУНА́К БӘК** (? — 1552), морза. *Чапкын бәк Отыч улының* бертуганының улы. Казанны Иван IV гаскәрләреннән яклау сугышы җитәкчеләренең берсе. *Казанның яулап алынуы* (1552) вакытында морза *Япанча* һәм Явыш бәк б-н бергә рус гаскәре тылында хәрәкәт итә.

*Әд.:* А л и ш е в С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995.

**ШУРА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Иләт елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 8,8 *км*, ТР чикләрендә — 18,8 *км*. Бассейнының мәйданы 487,4 $км^2$. Вятка увалы калкулыгыннан ага. Елга башы һәм тамагы Мари Респ-касында, ТРына елганың Арча һәм Әтнә р-ннарындагы 2 участогы керә. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 98 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 65%. Ш.ның 0,6 дан 14,7 *км* га кадәр озынлыктагы 20 кушылдыгы бар, аларның күпчелеге Мари Респ-касы терр-ясендә. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә күбрәк. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**ШУРА́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 50 *км* төньяктарак, Шура елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 257 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ташлынур Пүчинкәсе буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт

крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта сугу, такта яру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, су тегермәне, вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 951,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 415, 1897 дә — 590, 1908 дә — 681, 1920 дә — 642, 1926 да — 589, 1938 дә — 636, 1949 да — 500, 1958 дә — 515, 1970 тә — 523, 1979 да — 432, 1989 да — 309, 2002 дә — 293 кеше.

**«ШУРА́»**, иҗтимагый-агарту һәм әдәби-публицистик журнал. 1908 елның 10 гыйнварыннан 1917 нең 31 декабренә кадәр Оренбургта татар телендә нәшер ителә, барысы 240 саны чыга. Айга 2 тапкыр *«Вакыт»* г-тасының кушымтасы буларак басыла. Наширләре — М.Рәмиев, аннары З.Рәмиев (*Дәрдемәнд*), мөхәррире — Р.*Фәхретдин*. Редакция составына Ф.*Кәрими*, К.*Бәкер*, Ш.*Камал* керә, журнал б-н Й.Акчура, З.Бәшири, М.Бигиев, Я.Вәли, Җ.Вәлиди хезмәттәшлек итә. Алтын прииcкасы хуҗалары *Рәмиевләрнең* финанс ярдәме б-н «Ш.» даими югары полиграфик дәрәҗәдә чыга. Аның төп юнәлеше Россия мөселманнары, беренче чиратта татарлар тормышын яктырту була. Мәкаләләр дини, тарихи, мәгариф, әдәби, мәдәни, хатын-кызлар азатлыгы кебек мәсьәләләрне үз эченә ала. Сәяси бүлеге булмый, сирәк кенә рус матбугатыннан күчереп басу б-н чикләнә. Мөселман бергәлеген модернизацияләүне яклый, ислам б-н алгарышның, фән һәм диннең үзара ярашуын дәлилли (М.Бигиев). «Ш.»да әлекке мөселман мәдәнияте тарихына һәм исламның асылын аңлатуга багышланган тарихи-фәлсәфи язмалар циклы басыла; мөселман, аеруча төрки дөньяның бердәмлеге ассызыклана. Пед., мәктәп гигиенасы мәсьәләләренә һәм укыту методикасына зур игътибар бирелә. Агарту характерындагы язмаларда Европа, бигрәк тә рус мәдәниятенең тәэсире ачык чагыла. «Атаклы кешеләр һәм мөһим вакыйгалар» бүлегендә күренекле галимнәрнең хезмәтләренә бәяләмәләр һәм тарихи истәлекләргә тасвирламалар бирелә. Журнал битләрендә татарларның килеп чыгышы, Идел буе Болгары, Алтын Урда, Казан ханлыгының роле турында бәхәсләр яктыртыла (З.Вәлиди, Һ.Атласи, Р.Фәхретдин һ.б.). «Хикәяләр, шигырьләр, юмор һәм мәкальләр» дигән зур бүлеге була. Оригиналь әсәрләр б-н беррәттән төрек, фарсы, Европа телләреннән тәрҗемәләр, ш.у. яшь язучылар (И.Башмаков, Х.Исхакый, Ә.Сәгыйди, М.Фәйзи, З.Ярмәки) һәм күренекле язучыларның (Ш.Камал, Г.Ибраһимов, Г. Тукай, Ә.Галимов, Г.Баттал, Я.Айманов) әсәрләре басыла. Редакция татар әдәби теленең үз нигезендә үсүен яклый; татар әдәби телендә язылган иң яхшы әсәргә бәйге оештыра, «Болгар кызы» хикәясе б-н М.Гафури җиңүгә ирешә. Р.Фәхретдин, Г.Ибраһимов, Г.Баттал һ.б.ның әдәбият белеме буенча һәм тарихи-әдәби язмалары басыла. «Библиографик күзәтүләр һәм тәнкыйть» бүлегендә яңа китапларга аннотацияләр бирелә. Чыгу дәвамында басма күренекле татар журналларының берсе була, төрки халыклар арасында киң тарала. ХКСның «Матбугат турында» Декреты чыгудан соң ябыла.



«Шура» журналы.

*Әд.:* Г о с м а н о в М.Г., М ә р д а н о в Р.Ф. «Шура» журналының библиографик күрсәткече. К., 2000; М ә р д а н о в Р.Ф. «Шура» журналы (1908–1917): әдәбият мәсьәләләре. К., 2001; Г а й н у л л и н М. Татарская литература и публицистика начала XX в. К., 1966.

**ШУРАБА́Ш** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 48 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шура елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 448 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 52%, марилар — 31%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шишоры, Богашевская Пустошь буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез басу, тимерчелек б-н шөгыльләнә, юлаучылар йорты тота. 20 йөз башында Ш.та мәчет, тимерче алачыгы, 3 юлаучылар йорты, 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1196,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 335, 1897 дә — 551, 1908 дә — 629, 1920 дә — 689, 1926 да — 462, 1938 дә — 462, 1949 да — 325, 1958 дә — 242, 1970 тә — 504, 1979 да — 452, 1989 да — 408, 2002 дә — 398 кеше.

**ШУРА́ЕВ** Александр Сергеевич (13.9.1948, Мәскәү), хәрби дирижёр, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986). 1971 елда Мәскәү консерваториясен тәмамлый. Үзәк гаскәрләр төркемендә (Чехословакия), Байкал арьягы һәм Идел буе хәрби округында хәрби дирижёр булып эшли. 1983–94 тә Казан югары артиллерия инженер-командирлар уч-щесендә тынлы оркестр башлыгы. 2005 тән Казан консерваториясендә дирижёрлык һәм инструментовка класслары алып бара.

**«ШУРАМПУ́С»** («Шурăмпуç» — «Таң»), иҗтимагый-сәяси, фәнни һәм әдәби журнал. РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты каршындагы Үзәк чуаш бүлеге органы. 1919 елның гыйнварыннан 1921 гә кадәр Казанда чуаш телендә нәшер ителә, барысы 18 саны чыга. Мөхәррирләре — А.Лукин, Е.Фадеев, Н.Андреев. Сәясәт бүлегендә — совет хөкүмәтенең декретлары һәм карарлары, хуҗалык, хәрби эшчәнлек мәсьәләләре буенча материаллар, гражданнар сугышы фронтларыннан хәбәрләр, фәнни бүлектә — тарих, геогр., мед. (аерым алганда, эпидемик авырулар һәм аларны кисәтү чаралары турында тәэфсилләп хәбәр ителә; мед. буенча мәкаләләр авторлары арасында — С.Вишневский) буенча язмалар; әдәби бүлектә К.Ивановның «Нарспи» поэмасы, Ф.Павловның «Мәхкәмәдә» («В суде») комедиясе, М.Фёдоровның




«Шурампус» журналы.

«Урман иясе» («Леший») балладасы, яшь язучыларның гражданнар сугышы романтикасына дан җырлаган хикәяләре һәм шигырьләре дөнья күрә. «Ш.» укучыларын рус язучылары әсәрләре — И.Крылов мәсәлләре, Л.Н.Толстойның «Барлык сыйфатлар да аңардан» («От ней все качества») комедиясе, А.П.Чехов хикәяләре һ.б. б-н таныштыра. Чуаш язучылары И.Н.Юркин, Г.Тал-Мрза (Зайцев), Ф.П.Павлов хезмәттәшлек итә. 1919–20 дә тиражның күп өлеше Кызыл Армия частьларына таратыла. 1995 нең июненнән *«Сувар»* г-тасының шул ук исемдәге әдәби кушымтасы буларак басыла (4 сан). Мөхәррирләре — Н.М.Сорокин, А.Г.Иванов, К.А.Малышев. Татарстанда яшәүче чуаш шагыйрьләре, прозаиклары, публицистларының (В.Юдин, В.Ашкеров, Н.Зимин, В.Орлов һ.б.) шигырьләре, җырлары, хикәяләре, очерклары, татар шагыйрьләре һәм язучылары әсәрләренең тәрҗемәләре басыла.

*Әд.:* С о р о к и н Н. Занялась «Заря» чувашская // Татарстан. 1996. № 1.

**ШУРА́Н** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 13,4 *км*. Бассейнының мәйданы 107,7 *км*$^2$. Елга башы Балык Бистәсе р-ны Казаклар авылыннан 4 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Лаеш р-ны Шуран авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычының терәк сулары астында калган. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Ш.ның 1,2 дән 4,4 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,25 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Ш. бассейнында суының гомуми күләме 0,98 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШУРА́Н** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 27 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 226 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — балык тоту. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Алпавыт А.П.Нармацкий йорты (18 йөз уртасы архит-ра истәлеге). 1620–21 дән Пустошь Шуран исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балык тоту, Кама аша йөк ташу б-н шөгыльләнә. 18 йөз уртасында авыл хуҗаларының берсе — «Нормандия герцогы» кушаматлы капитан А.П.Нармацкий үзенең хезмәтчеләре һәм качкыннар б-н Камада талап йөри. Бу хәлләр А.А.Бестужев-Марлинскийның «Латник» романында (СПб., 1889) чагыла, әсәрдә Ш. авылы да тасвирлана. 20 йөз башында Христово-Рождество чиркәве (1735 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1869 да ачыла), 6 тегермән, тимерчелек алачыгы, Аеклар җәмгыяте уку залы, атлы почта станциясе, этап йорты, казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 480 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Чырпы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 462 ир-ат; 1859 да — 592, 1897 дә — 656, 1908 дә — 676, 1920 дә — 751, 1926 да — 764, 1938 дә — 669, 1949 да — 376, 1958 дә — 424, 1970 тә — 403, 1979 да — 236, 1989 да — 181, 2002 дә — 247 кеше. Ш. янында Болгар һәм Алтын Урда чорының Кашан шәһәре хәрабәләре саклана.

*Әд.:* История Лаишевского края. К., 1997.

**ШУРА́Н ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, к. *Гремячий Ключ шәһәрлеге.*

**ШУРТАКО́ВА** Тамара Васильевна (14.2.1930, Вологда өлкәсенең Великий Устюг ш. — 20.8.2003, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук (2002 елга кадәр) пед. кафедрасында эшли. Бер үк вакытта, 1960–61дә, тарих-филол. ф-ты деканы урынбасары, 1970–75 тә укытучыларның квалификациясен күтәрү ф-ты деканы. Хезмәтләре Казан ун-ты тарихына, эстетик тәрбия мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Руководство Казанского университета развитием начального и среднего образования в Казанском учебном округе в 1805–1836 гг. К., 1959; Музыкально-художественное воспитание учащихся. К., 1971 (автордаш); Формирование мировоззрения студентов средствами искусства. К., 1987.

**ШУРЫ́ГИН** Вадим Васильевич (23.1.1952, Мәскәү), математик, геометр, физика-матем. фән. д-ры (1999), проф. (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1974), шунда ук эшли, проф. (1999–2006), геом. каф. мөдире (2007 дән). Хезмәтләре алгебраик структуралы күптөрлелекләр геометриясенә һәм югары тәртипле дифференциаль геометриягә карый. Ш. алгебралардан өстен фәзалар теориясе нигезендә югары тәртипле геом. структураларны тикшерү алымын эшли; локаль алгебралардан өстен күптөрлелекләр өчен Вайсман -Молино когомологияләре аналогын төзи, бу исә әлеге күптөрлелекләрдәге голоморф бәйлелекләр барлыгы мәсьәләсен хәл итүне мөмкин кыла. Локаль алгебрадан өстен күптөрлелекнең агынтылар катламлануына эквивалентлы булуы мәсьәләсен хәл итә (кайсыдыр нәабель бәйләмендәге коэффициентлы когомологияләр тривиальлеге атамаларын кулланып); кайсыдыр төп катламлы катламлануга ярашырдай Молино когомологияләренең Атья классын төзи; бу класс исә локаль алгебрадан өстен күптөрлелектә Эресман бәйлелекләре хасил булуга юл куймый.

Х е з м.: Пространства над алгебрами. К., 1985 (автордаш); Многообразия над алгебрами и их применение в геометрии расслоений струй // Успехи мат. наук. 1993. Т. 48, вып. 2; Гладкие многообразия над локальными алгебрами и расслоения Вейля // Итоги науки и техники. Соврем. математика и её приложения. 2002. Т. 73; On the higher order geometry of Weil bundles over smooth manifolds and over parameter-dependent manifolds // Lobachevskii J. Math. 2005. V.18 (автордаш).

**ШУ́ТИКОВ** Анатолий Иванович (6.7.1946, Калуга өлкәсенең Козельск ш.), дирижёр, педагог, проф. (1991), ТАССРның һәм РСФСР-



А.И.Шутиков җитәкчелегендәге оркестр.



А.И. Шутиков.

ның атказ. сәнгать эшлеклесе (1979, 1986), РФнең халык артисты (2007). 1971 елда Казан консерваториясен (И.Шәриповның баян классы) тәмамлый. 1971–89 да Казан мәдәният ин-тында укыта, студентлардан оешкан халык музыка уен кораллары оркестрлары б-н җитәкчелек итә. 1989–93 тә Казан консерваториясендә (1990 нан халык музыка уен кораллары каф. мөдире). 1993 тән үзе оештырган һәм күп кенә халыкара фестивальләр лауреаты булган *Татарстан Республикасының Дәүләт халык музыка уен кораллары оркестрының* сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижёры, Европа илләрендә гастрольләрдә йөри, мәшһүр башкаручылар б-н хезмәттәшлек итә. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2001). Медаль б-н бүләкләнә.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ШУША́Р** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 5 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казансу елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 82 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек.



Шушар авылындагы Воскресение чиркәве. 1898. 20 йөз башы фоторәсеме.

1620 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Каймар Мамыш, Каймармыш, Шишкинское Баково исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Воскресение чиркәве (1898 дә төзелә), земство мәктәбе (1881 дә ачыла), су тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 365 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 45, 1782 дә — 32 ир-ат, 1859 да — 190, 1897 дә — 217, 1908 дә — 235, 1920 дә — 222, 1926 да — 261, 1938 дә — 266, 1949 да — 258, 1958 дә — 236, 1970 тә — 249, 1989 да — 112, 2002 дә — 84 кеше.

**ШУШИРМӘ́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 29 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 254 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1647–52 еллардан Иске Шуширмә буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шебазово исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.дә мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1249 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 156 ир-ат; 1859 — 601, 1897 дә — 1141, 1908 дә — 1540, 1920 дә — 1236, 1926 да — 867, 1938 дә — 671, 1949 да — 435, 1958 дә — 440, 1970 тә — 490, 1979 да — 423, 1989 да — 318, 2002 дә — 274 кеше.

**ШУШМА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Вятка елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 100,2 *км*, ТР чикләрендә — 81,1 *км*. Бассейнының мәйданы 1900 *км*². Елга башы Мари Респ-касы б-н чиктәш Арча р-ны Яңа Ашыт авылыннан 5 *км* төньяк-көнбатыштарак. Арча һәм Балтач р-ннары терр-ясе буйлап, Кугубор елгасы тамагыннан түбәндәрәк — Киров өлкәсе терр-ясеннән ага, Малмыж шәһәреннән көнчыгыштарак Вятка елгасына коя. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 59 *м*. Су җыелу мәйданы ерым һәм сызалар б-н ергаланган калкулыклы асимметрияле тигезлектән (сулъяк яр өлеше шактый зур) тора. Ш. үзәне асимметрияле, әле сул, әле уң сөзәклекләре текәрәк; түбән һәм урта агымында киңлеге 2–3 *км*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Күпчелекне нарат һәм нарат катыш киң яфраклы урманнар тәшкил итә, сулъяк ярда шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан көнбатыштарак имәнлекләр үсә. Нигездә, субүләр мәйданы сукаланган; тугае ике яклы, болын, көтүлек һәм торфлыклардан тора. Елга юлы бормалы, киңлеге күбесенчә 6–8 *м* тәшкил итә. Агым тизлеге плёсларда 0,1–0,2 *м/с* һәм сайлыкларда 0,3–0,4 *м/с*. Ш.ның су җыелу мәйданында күзәтелүче эрозия процесслары кушылдыкларының 44 кә кадәр артуына китерде. ТРда иң зурлары: Нысы (13,4 *км*), Сәрдә (21 *км*), Шубан (11,4 *км*), Көшкәт (26 *км*), Арбор (31,3 *км*), Кугубор (44,9 *км*) — сул кушылдыклар; Хәтнә (16,3 *км*), Норма (13,1 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елга режимын күзәтүләр Балтач р-ны Зур Лызи авылы янындагы су үлчәгеч постта алып барыла (1977 елдан). Ел сезоннары буенча агымның бүленеше тигез түгел. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 129 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 108 *мм*. Аеруча мул сулы көчле агым язгы ташу вакытына (апрельнең беренче ункөнлегендә) туры килә. Суның иң зур чыгымы 149 *м*³/*с* (1980). Суының иң аз вакытында елга биеклеге тотрыклы, бу чорда елга грунт сулары исәбенә туена; җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–3 *л/с·км*². Елга ноябрь уртасында туңа. Боз кату 150 көн дәвам итә. Кыш ахырына бозның калынлыгы 97 *см* га җитә; елганың грунт сулары чыккан аерым урыннары кыш буена бөтенләй диярлек боз б-н капланмый. Елга озынлыгында суның катылыгы нык үзгәрә: язын суы югары агымында уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), урта һәм түбән агымында йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*); җәйге һәм кышкы суы иң аз чорда югары агымында — бик каты (12–20 *мг-экв/л*), урта агымында һәм тамак өлешендә уртача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 7,2 млн. *м*³ булган 17 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. Ш. һәм аның кушылдыкларының яр буенда яхшы сыйфатлы җир асты су чыганаклары күп. Ш. — ТРның табигать истәлеге (1978).



Шушма елгасы. Балтач районы.

**ШУШМА́ ГОРИЗОНТЫ́**, (Шушма елгасы исеменнән), Пермь системасы *Уфа ярусының* югары өлешендәге тау токымнары катламы, Татарстан терр-ясендә 260 млн. ел элек барлыкка килә. 200 *м* га кадәр калынлыктагы кызыл төстәге континенталь, нигездә, комсу-балчыксыл утырмалардан тора, респ-каның көнчыгышында очрый, Әтнә-Питрәч-Аксубай линиясеннән көнбатышка таба Ш.г. юкка чыга. Кызгылт-көрән, сирәк кенә яшькелт-коңгырт һәм яшькелт-соры балчыкларның, аргиллит, мергель, алевролит, комташ, известьташ, конгломератларның чиратлашуы хас; югары катламнары нык кына гипслы. Төче су лагуналары организмнарының (моллюсклар, кысласыманнар, суүсемнәр) ташка әйләнгән калдыклары, тропик һәм субтропик үсемлекләрнең серкә һәм споралары очрый.

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

**ШУШМАБА́Ш** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 38 *км* төньяктарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 994 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында По обе стороны речки Шошмы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон тетү, чыпта сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.та мәчет, 2 су тегермәне, тимерче алачыгы, салат з-ды, зур һәм кечкенә кибет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1272,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 270, 1897 дә — 608, 1908 дә — 708, 1920 дә — 696, 1926 да — 615, 1938 дә — 637, 1949 да — 528, 1958 дә — 525, 1970 тә — 947, 1979 да — 957, 1989 да — 929, 2002 дә — 992 кеше.

**ШУЫШМАЛА́Р**, тау токымнарының авырлык көче тәэсирендә сөзәклекләр буйлап шуышып күчүе. Ш. ешрак комсу су горизонтлары булган балчыксыл токымнарда барлыкка киләләр. Юылу нәтиҗәсендә сөзәклекләрнең текәлеге арту, ш.у. сөзәклекләр ясаучы тау токымнарының нык юешләнгән булуы шуышу процессы тудыра. Шуышулар вакытында сөзәклектә ярымтүгәрәк уем (шуышма циркы), сөзәклек итәгендә — сөзәклеккә таба авыш террасалар яки кечкенә калкулыклы рельеф хасил була. Татарстанда шуышу процессының үсеше барыннан да бигрәк геол.-геоморфол. һәм гидрогеол. шартлар б-н билгеләнә. Аеруча көчле Ш. эшчәнлеге Идел алдының көньягында күзәтелә, аның геол. төзелешендә акбур системасының түбән һәм Юра системасының югары бүлекләренең комсу катламнарында су горизонтлары булган балчыклар катнаша. Шулай ук Ш. респ-каның башка районнарында да күзәтелә: Пермь (татар ярусы) һәм неоген системаларының балчыклы-мергельле токымнарында үсеш алган. Гадәттә, алар 12° тан 30–35° ка кадәрге текәлектәге сөзәклекләрдә барлыкка киләләр, текәлек тагын да зуррак булганда ишелмәләр (зур кисәкле токымнарның җимерелүе) б-н алышыналар. Иң актив Ш. Тәтеш шәһәреннән түбәндәрәк Идел елгасы үзәненең юылучан уңъяк биек сөзәклекләрендә таралган. Урыны-урыны б-н алар Кама, Вятка һ.б. елгаларның текә сөзәклекләрендә очрыйлар. 0,5 *км* га һәм аннан артыграк диаметрлы булган цирксыман Ш. өстенлек итә. Шуышма матдәләр еш кына блоксыман баскычлы структурага ия, балчыклы тау битләрендә сирәк кенә шуышма агымнар барлыкка килә. Явым-төшемнәр күп булган елларда шуышу процессы активлаша, алар исә тау токымнарының нык кына дымлануына, җир өсте һәм җир асты агымнарының көчәюенә китерә. Урта Идел буендагы кебек Татарстанда да аномаль интенсив Ш. 1979 һәм 1990 елгы күп карлы кышлардан соң күзәтелә. Коры елларда шуышу процессы көчсезләнә. Ш.ның барлыкка килүенә борынгы заманнарда плиоценның гумид климатларында һәм дүртенчел системаның бозлыкара чорында уңай шартлар тәэсир ясый, күмелгән Ш.ның очравы моңа мисал булып тора. Ш. торак пунктларга, элемтә юлларына,

нефть-газ үткәргечләргә һ.б.га куркыныч тудыра. Ш.га каршы көрәш чаралары: сөзәклек итәкләрен ныгыту (аларны юылудан саклау өчен), җир өсте һәм җир асты суларын дренажлау, шуышма блокларны ныгыту.

*Әд.:* Гидрология СССР. Т. 13. Поволжье и Прикамье. М., 1970; Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

*А.П.Дедков.*

**ШҮРӘ́ ӘРГӘ́Н**, татар халкының тынлы музыка уен коралы. *Кәтүк сыбызгыдан* үзгәртелгән. Төрле зурлыктагы берничә агач кәтүктән ясала, аларга юка каен элпәсе яки резина тасма тарттырып беркетелә. Көйләгәннән соң, һәр кәтүк җеп б-н беркетелә. Ш.ә. диапазоны октавадан алып дуодецимага кадәр тибрәнә. Аваз көче өреп кертелгән һава агымының басымына бәйле. Әлеге музыка уен коралының авазы кискен, тембры обертоннарга бай түгел, динамик мөмкинлекләре – mp дан алып f га кадәр, диапазоны кәтүкләр санына бәйле. Алар артканда интонация аеруча тотрыклы була, авазлар җиңел һәм чиста яңгырап чыга. Музыка уен коралы терцияләр яки квартлар буенча көйләнә. Катнаш көйләү ысулы да кулланыла (терция-ква́рталы).

*Р.Ф.Халитов.*

**ШҮРӘЛЕ́**, татар мифологиясе һәм фольклорында урманда яшәүче рух. Озын бармаклы, кайчакта мөгезле, йөнтәс ир-ат яисә шәрә хатын-кыз кыяфәтендәге зат. Эттән, судан курка: шүрәле очраса, инеш яисә күл ягына йөгерергә кирәк. Кешеләрне урманга алдап алып керә, аларны үтергәнче кытыкларга мөмкин. Бер урманда берничә Ш. яшәве ихтимал. Татар фольклорының күп кенә әсәрләре персонажы. Мифологик хикәяләрдә 3 сюжет киң таралган. Беренчесендә тапкыр егет Былтыр урманга утынга бара, Ш.нең бармагын тумранның ярыгына куярга куша һәм чөйне бәреп чыгара, Ш.нең бармагы кысылып кала («Былтыр кысты»). Икенче сюжетта һәр төнне Ш. атланып чапкан атның сыртына хуҗасы сумала сылап җибәреп, аны кулга төшерә («Шүрәле куаклыгы»). Өченче сюжетта Ш. бер картны урманга алып кереп адаштыра, мулланың догалары ярдәмендә карт урманнан исән-имин чыга («Шүрәле»). Ш.не киемнең кире ягын киеп тә алдап була («Шүрәлене ничек алдарга?»). Ш.нең кан тамчысыннан берничә яңа Ш. барлыкка килә («Шүрәле каргаган авыл»). Урманда яшәгән рух темасы



Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасына иллюстрация. 1937. Рәссамы — Б.М.Әлминов.

күп кенә әдәби, сынлы сәнгать, муз. әсәрләрдә чагылыш таба. Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасы аеруча киң таныла. Поэмага иллюстрацияләр авторлары — Б.И.Урманче, Б.М.Әлмәнов, Ф.Г.Әминов һ.б. Ф.Яруллин шул ук исемдә балет иҗат итә.

*Әд.:* Коблов Я.Д. Татар халык иҗаты: Риватьләр һәм легендалар. К., 1987; Мифология Казанских татар. К., 1910; Замалетдинов Л.Ш. О мифологической основе сказки «Шурале» // Габдулла Тукай: Материалы науч. конф. К., 1979.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«ШҮРӘЛЕ́»**, балет, 3 пәрдәдә (Г.Тукайның шул исем. әкиятенә һәм татар халык әкиятләренә нигезләнә). Композиторы — Ф.Яруллин, Ә.Фәйзи һәм Л.Якобсон либреттосы. Балет постановкасы 1941 елның августында узачак Мәскәүдәге Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы өчен әзерләнә (хореограф һәм сәхнәгә куючы Л.Якобсон). Бөек Ватан сугышы башлану б-н бәйле рәвештә, премьераны кичектереп торалар, ул бары тик 1945 тә генә Татар опера һәм балет театрында күрсәтелә: Л.Жуков (1 нче һәм 3 нче күренешләр), Г.Таһиров хореографиясе һәм постановкасы (2 нче күренеш), дирижёры И.Әүхәдиев, рәссамы П.Сперанский, төп партияләрне башкаручылар — Б.Әхтәмов (Былтыр), А.Гацулина (Сөембикә), В.Романюк (Шүрәле). «Ш.»нең аннан соңгы постановкалары 1953 тә (Я.Брунак хореографиясе һәм постановкасы, дирижёр Х.Фазлуллин, рәссам П.Сперанский, төп партияләрне башкаручылар — Ә.Нарыйков, Н.Юлтыева, Б.Әхтәмов, Р.Садыйков); 1957 дә (Л.Бордзиловская һәм Ш.Байдәүләтова хореографиясе һәм постановкасы, дирижёр Х.Фазлуллин, рәссам П.Сперанский, төп партияләрне башкаручылар — Ә.Нарыйков, К.Янбулатова, С.Хәйруллин. Спектакль Мәскәүдәге Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында күрсәтелә); 1970 тә (Л.Якобсон хореографиясе, Ю.Дружинина һәм Н.Юлтыева постановкасы, дирижёр Х.Фазлуллин, рәссамнар Л.Мильчин һәм Ә.Нагаев, төп партияләрне башкаручылар — К.Гайнуллин, С.Хантимерова, С.Хәйруллин); 1986 да (Л.Якобсон хореографиясе, театр редакциясендә К.Рассадин постановкасы, дирижёр Т.Әхмәтов, рәссам А.Кноблок, төп партияләрне башкаручылар — Р.Әбелханов, И.Хәкимова, В.Яковлев); 2000 дә (Л.Якобсон хореографиясе, В.Яковлев постановкасы һәм редакциясе, дирижёр В.Васильев, рәссам А.Кноблок, төп партияләрне башкаручылар — Б.Смагулов, Е.Щеглова, В.Яруллин) була. Соңгы постановка хәзерге вакытта да театр репертуарына кертелә, спектакльдә катнашу өчен Зур һәм Мария театрларының әйдәп баручы солистлары А.Петухов, И.Зиброва, А.Тимофеев, Т.Голякова, Евг. Образцова һ.б. берничә тапкыр Казанга килә. 1987 дән «Ш.» балеты ел саен *Нуриев Р. исемендәге классик балет фестивале* программасына кертелә.

«Ш.» балеты илебезнең күп кенә театрларында, ш.и. Зур театрда (1955, 1960), С.М.Киров исем. Ленинград акад. опера һәм балет театрында (хәзер Мария театры; 1950, 2009), Саратов, Новосибирск, Киев, Одесса, Львов, Алма-Ата, Ташкент, Вильнюс һ.б. шәһәрләрдәге театрларда; чит илләрдә — Болгария (София, 1956), Монголия (Улан-Батор, 1958), Польша (Бытом, 1960), Чехословакия (Оломоуц, 1961), ГДР (Росток, 1968), Мексика (Мехико, 2002) һ.б.да куела. Атаклы башкаручылар арасында төрле вакытларда Ю.Григорович, В.Васильев, М.Плисецкая, Ш.Яһүдин, И.Белецкий, Н.Дудинская, А.Макаров була. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (вафатыннан соң комп. Ф.Яруллинга бирелә, 1958). 1980 дә С.М.Киров исем. Опера һәм балет театрында куелган







«Шүрәле» балетыннан күренешләр: 1. 1953 ел. Рольләрдә: Шүрәле – Б.Әхтәмов, Сөембикә – Н.Юлтыева; 2. 1957 ел. Шүрәле ролендә – С.Хәйруллин; 3. 2011 ел. Рольләрдә: Шүрәле – Р.Савденов, Сөембикә – Т.Голякова, Былтыр – А.Белов.

спектакль буенча «Урман әкияте» («Лесная сказка», реж. О.Рябоконь) дип аталган фильм-балет төшерелә.

*В.Н.Горшков, Р.И.Такташ.*

**ШЫГА́Й** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 26 *км* төньяктарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 286 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.да мәчет, су һәм җил тегермәне, тимерче алачыгы, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 983 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ивановка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 58 ир-ат; 1859 да — 376, 1897 дә — 780, 1908 дә — 877, 1920 дә — 837, 1926 да — 852, 1938 дә — 816, 1949 да — 502, 1958 дә — 451, 1970 тә — 500, 1979 да — 408, 1989 да — 279, 2002 дә — 321 кеше.

**ШЫГА́Й** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 20 *км* төньяктарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 215 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ш.да 2 мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, ашлык саклау-сату һәм 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1513,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Язикәү волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 151 ир-ат; 1834 тә — 422, 1870 тә — 778, 1897 дә — 1072, 1906 да — 1139, 1920 дә — 1220, 1926 да — 1015, 1938 дә — 949, 1949 да — 594, 1958 дә — 430, 1970 тә — 304, 1979 да — 316, 1989 да — 179, 2002 дә — 207 кеше.

**ШЫКМА́Й** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 36 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зичә елгасы буенда. 2010 елда 166 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөз ахырында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта һәм тукыма туку, мич чыгару, чана һәм арба ясау, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Ш.да мәчет, мәдрәсә, 2 су тегермәне, ярма яргыч, ашлык саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1527 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 471, 1897 дә — 904, 1906 да — 957, 1913 тә — 1235, 1920 дә — 1320, 1926 да — 831, 1938 дә — 878, 1949 да — 682, 1958 дә — 701, 1970 тә — 665, 1979 да — 478, 1989 да — 256, 2002 дә — 203 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ШЫЛАҢГЫ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 763 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1665–67 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Бистюрлеев Враг исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашман хезмәтен үти; игенчелек, терлекчелек, күмер җитештерү, такта яру, балта эше, сәүдә б-н шөгыльләнә; Донбасс шахталарына эшкә китә. 20 йөз башында 3 мәчет, 3 мәдрәсә, 10 сәүдә һәм 8 сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1622,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Мөчәли волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 909, 1897 дә — 1363, 1913 тә — 1980, 1920 дә — 2009, 1926 да — 2044, 1938 дә — 2074, 1949 да — 1659, 1958 дә — 1537, 1970 тә — 1981, 1979 да — 1475, 1989 да — 846, 2002 дә — 795 кеше.

**ШЫЛАҢГЫ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 32 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы буендагы пристань. 2010 елда 1060 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Сөт һәм 2 кирпеч з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 16 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский исеме б-н дә билгеле. Халкы башта сарай крәстияннәре (1693 тә Ш. патшаның туганы К.А.Нарышкинга бүләк ителә, 1861 елгы реформага кадәр Нарышкиннар нәселе милке булып тора) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, бакчачылык, умартачылык, он тарту, тегү, алебастр чыгару, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Христово-Рождество чиркәве (1783–86 да төзелә; архит-ра истәлеге, хәзер дә эшли), земство мәктәбе (1867–74 тә булган чиркәү-приход мәктәбе урынына 1879 да ачыла), телефон, китапханә-уку залы, 4 су һәм 6 җил тегермәне, пароход пристане, 4 сыраханә, 1 казна-шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1577 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ташёвка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 842 ир-ат; 1859 да — 1077, 1897 дә — 1043, 1908 дә — 857, 1920 дә — 1367, 1926 да — 1346, 1938 дә — 1989, 1949 да — 1616, 1958 дә — 1506, 1970 тә — 1239, 1979 да — 1114, 1989 да — 1284, 2002 дә — 1198 кеше. Ш. тирәсендә сәламәтләндерү лагерьлары һәм ял базалары урнашкан.



Шылаңгы авылындагы Рождество-Христово чиркәве. 1783–86.

**ШЫНКЕ́ВИЧ** Якуб (16.4.1884, Минск губ. Лаховичи а. — 1.11.1966, АКШ), Польша-Литва татарлары мөфтие (1925–39), философия д-ры (1925). Минск реаль уч-щесен тәмамлаганнан соң (1904), Петербург технол. ин-тында һәм Петербург ун-тында укый. Укыган елларда *Польша-Литва татар студентлары түгәрәге* әгъзасы була (С.-Петербург). Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Россия армиясенә мобилизацияләнә. 1917 нең көзенә кадәр фронтта була; 1918–19 да Кырымда, соңыннан Германиядә. Берлин ун-тын тәмамлый (1925). 1925 нең декабрендә *Бөтенпольша мөселманнары гминасы вәкилләре съездында* читтән торып мөфти итеп сайлана. 1926 дан Польшада. Бөтендөнья мөселманннары (1926, Каһирә), Бөтеневрoпа мөселманнары (1935, Женева) конгрессларында катнаша. *Бөтенпольша мөселманнары конгрессын* оештыручыларының һәм җитәкчеләренең берсе (1938). Икенче бөтендөнья сугышы елларында Мисырга эмиграцияли. 1957 дә АКШка күченеп китә.

*Әд.:* Гришин Я.Я. Польско-литовские татары: взгляд через века. К., 2000.

*Я.Я.Гришин.*

**ШЫПШЫЕ́К** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 30 *км* төньяктарак, Сола елгасының (Казансуның уң кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 2 кеше (татарлар) яши. 1650 ләрдән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда По речке Мокше, Алан Шепшек исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тукыма туку, кирпеч сугу, олаучылык, урман кисү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, вак-тө-

якләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 501,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 28 ир-ат; 1859 да — 246, 1897 дә — 396, 1908 дә — 563, 1920 дә — 528, 1926 да — 545, 1938 дә — 420, 1949 да — 310, 1958 дә — 163, 1970 тә — 104, 1989 да — 9, 2002 дә — 2 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ШЫРПЫ́ ҖИТЕШТЕРҮ́**, Казан губернасында. 20 йөз башында губернада Чистай өязе Күлбай-Мораса авылында бертуган З. һәм С.Сәйфуллиннарның (1895 елда ачыла, төп капиталы 3 мең сум, 50 эшче, еллык җитештерү күләме 24 мең сум), Чистай өязе Ялаур авылында М.В.Колчуринның (1904 тә нигезләнә, төп капиталы 20 мең сум, 40 эшче; 10 ат көчле егәрлекле локомобиль б-н тәэмин ителгән, еллык җитештерү күләме 56 мең сум), Казан өязе Юртыш авылында Ш.Хәмитовның (36 эшче), Козьмодемьянск шәһәрендә С.Д.Мягчилованың, Күлбай-Мораса авылында С.Шабанов, Н.Садыйков һәм Ә.Кәримовларның шырпы ф-калары эшләп килә.

*Әд.:* Фабрично-заводские предприятия Российской империи. СПб., 1909.

**ШЫРТЛАВЫКЛА́Р** (Elateridae), төрле азык б-н тукланучылар асотрядыннан коңгызлар семьялыгы; а.х.культураларына зыян китерүче корткычлар. Дөньяда якынча 10 мең төре таралган, Татарстанда 60 төре бар, озынлыгы 7–20 *мм*, төсе төрле-төрле. Буйлы Ш. бик күп таралганнар, алар яткын җирләрдә, күпьеллык үлән чәчүлекләрендә яши. Аерым үзенчәлеге — аркасына яткан коңгыз шыртлаган тавыш чыгарып югары сикерә. Бар җирдә дә, бигрәк тә җиңел комсу, ачы туфракларда очрый. Ш. үлән б-н тукланалар. Личинкалары нечкә, озын, каты (чыбык личинка), акрын үсәләр (3–5 ел). Июль–августта курчакка әйләнәләр, яз көне коңгызлар барлыкка килә, йомыркаларын туфракка салалар, туфрак астындагы үсемлекләр аларга азык була. Личинкалары башта черемә б-н, аннары кыяклыларның орлыклары, тишемнәр, тамырчыклар, тамыразыклар һәм бүлбетамырлар б-н тукланалар; язгы бодайга, арпа, кукуруз, көнбагыш, чөгендер, бәрәңге h.б. культураларга зыян китерәләр. Төп көрәш чаралары: чәчү әйләнеше тәртибен саклау (чиста пар б-н), туфракны туңга төп эшкәртү, җирне һәм чәчүлекләрне чүпләрдән чистартып тору, орлыкларны агулау, чәчүлекләрдә агулы алдавыч җим куллану, чәчү әйләнешенә аз зарарлана торган культуралар (карабодай, җитен, тары, горчица) кертү.

*Әд.:* Б е й - Б и е н к о Г.Я. Общая энтомология. М., 1966; Ч е р е п а н о в а А.И. Вредители сельскохозяйственных культур и лесных насаждений. К., 1973. Т. 1.

*И.Н.Афанасьев.*

**ШЫЯ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Вятка елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 61 *км*. Бассейнының мәйданы 886,1 *км*². Мамадыш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Чиябашы (Никифирово) авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Гришкино авылыннан 6 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*. тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданы кушылдыкларның үзәннәре, ерым, сыза, уйсулыклар б-н



Шыя елгасы урта агымында.

тирән ергаланган, урыны-урыны б-н караңгы ылыслы-киң яфраклы урманнар үскән калкулыклы тигезлектән гыйбәрәт. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. Бассейны асимметрияле: аның сулъяк яр өлеше шактый зур. Үзәне бөтен озынлыгында асимметрияле: күбесенчә, сулъяк сөзәклекләр текәрәк. Елга юлы кайбер урыннарда бормалы, меандралар (бөгелешләр) б-н катлауланган (аеруча түбән агымында), киңлеге 40–50 *м* га кадәр, тирәнлеге сайлыкларда 0,5–1 *м*, плёсларда 2,5 *м* га кадәр. Ш.ның 22 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Баш-Арбаш (22 *км*), Оча (24 *км*), Өске (23 *км*), Юкәче (19,4 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*². Туенуы катнаш, өчтән ике өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–10 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 109 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 74 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 1,04 *м*³/*с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), язын һәм кышын уртача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Ш. бассейнында суының гомуми күләме 0,85 млн. *м*³ булган 6 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШЫЯ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кече Чирмешән елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 15,3 *км*. Бассейнының мәйданы 113,1 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән Әлки р-нында ага. Елга башы Йолдыз посёлогыннан 5 *км* көньяк-көнбатыштарак урман массивында, тамагы Татар Әхмәте авылыннан 4 *км* көньяктарак. Тамак өлеше Кече Чирмешән елгасының сазлыкланган уңъяк яр тугаенда урнашкан. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 75 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. Ш.ның 0,6 дан 12,5 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар, иң зурысы — Шыя елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,15 *км/км*². Туенуы катнаш, өчтән ике өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 73 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 50 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,006 *м*³/*с*. Озак вакыт яңгырлар булмаганда Ш. һәм аның кушылдыкларының аерым урыннары кибә. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Ш. бассейнында суының гомуми күләме 0,12 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ШЫЯ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Шыя елгасының (Кече Чирмешән елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 12,5 *км*. Бассейнының мәйданы 58,1 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән, Әлки р-нында ага. Елга башы Чёрная Речка посёлогының көнчыгыш кырыенда, тамагы Түбән Кәчи авылыннан көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. Ш.ның 0,7 дән 3,1 кмга кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә күбрәк. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Озак вакыт яңгырлар булмаганда елганың аерым урыннары кибә. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

# Щ

**ЩА́ПОВ** Афанасий Прокофьевич (5.10.1831, Иркутск губ., Верхоленск өязе Анга а. — 27.2.1876, Иркутск ш.), тарихчы, публицист, философ. Иркутск руханилар уч-щесен (1845), Иркутск руханилар семинариясен (1852), Казан руханилар академиясен (1856) тәмамлый. Казан руханилар академиясендә (1856–60), Казан ун-тында (1860–61) рус тарихын укыта. Студентларның яшерен *«Казан студентлары китапханәсе»* революцион түгәрәге әгъзасы, аның программасы авторы. Түгәрәк утырышларының берсендә Щ. «Конституция турында» лекциясен укый һәм анда: «Россиянең бөтен намуслы кешеләре»нең иң мөһим бурычы— хәбәрдарлык өчен көрәш. «Конституция сүз иреген бирергә һәм гарантияләргә тиеш», — ди. Аның фикеренчә, Пётр I дәверенә кадәр Россиядә булган «земство халык киңәшлеге» — халык үзе төзиячәк һәм «халык үзидарәсе рәвешендә дөньяга киләчәк» Конституциянең төп үрнәге. 1861 елның 16 апрелендә Казан губернасының Спас өязе Бизнә авылында атып үтерелгән крәстияннәрне искә алу уңаеннан үткәрелгән *Куртина чиркәвендәге панихидада* нотык сөйли, аны «Яшәсен демократик Конституция!» сүзләре б-н тәмамлый. Бу чыгышы өчен Щ.ны С.-Петербургка чакырталар, юлда чагында кулга алалар. Тикшерү вакытында император Александр II гә ике мөрәҗәгать яза, анда исә Россиядә үткәреләсе реформалар программасын бәян итә. Бу мөрәҗәгатьләргә эчке эшләр министры П.А.Валуев игътибар итеп, Щ.ны Россия Эчке эшләр министрлыгына чиновник итеп билгели. 1862 дә Щ. дәүләт хезмәтеннән китә; фәнни һәм публицистик эшләр б-н шөгыльләнә, «Современник», «Русское слово» ж-ллары б-н хезмәттәшлек итә. 1864 тә «ышанычсызлыгы» сәбәпле туган җиренә (Анга а.) сөрелә, бераздан Иркутскига күчерелә, анда гыйльми эшчәнлеген дәвам итә. «Дело», «Записки Сибирского отдела Русского Географического общества» ж-лларына языша. Рус геогр. җәмгыятенең Себер бүлеге идарәсе әгъзасы, этнограф буларак Туруханск краена (1866), Иркутск губернасының Верхоленск һәм Балаганск округларына (1874) оештырылган экспедицияләрдә катнаша. Туберкулёздан үлә. Хезмәтләре Себер, чиркәү таркалышы һәм иске дин тарафдарлары, 17 йөз земство соборлары тарихына карый. Щ. Казанга Соловки монастыреннан алып кайткан кульязмалар җыелмасы нигезендә «XVII йөздәге һәм XVIII йөзнең беренче яртысындагы рус чиркәвенең һәм гражданлыкның эчке халәтенә бәйләп рус иске дин тарафдарлыгы таркалашын тикшерү» («Русский раскол старообрядчества, рассматриваемый в связи с внутренним состоянием русской церкви и гражданственности в XVII веке и первой половине XVII века», 1858; 2 нче басмасы — 1859) темасына магистрлык диссертациясе яза. Казан ун-ты студентлары өчен әзерләгән лекцияләр курсын үзенең «земство өлкәчелеге» теориясенә нигезләп төзи: 1 нче бүлеге — «Өлкәләрне төзегәннән алып Болгавыр чорга кадәр рус халкы тарихының земство-өлкә формасы» («Земско-областная форма исторической жизни русского народа от основания областей до Смутного времени»), 2 нче бүлеге — «Рус халкы тарихының дәүләт-союз формасы (18 йөздән алып безнең заманга кадәр)» («Государственно-союзная форма исторической жизни русского народа (от 18 в. до нашего времени)»). Щ., башка рус тарихчыларыннан аермалы буларак, Россия тарихын кенәзләр һәм патшалар тарихы итеп түгел, ә бәлки халык тарихы итеп каравын ассызыклап әйтә. Ул Пётр I гә кадәрге Россия тарихын, община, вече, казаклар кругы, өлкә һәм земство советларын идеаллаштыра. Аның фикеренчә, ул чорларда һәр шәһәр үзенең өязе б-н бергә мөстәкыйль берәмлек, ирекле өлкә общинасын тәшкил иткән, «киң даирәле земстволы юридик төзелешкә һәм мөстәкыйль үсешкә» ия булган. Соңга таба, сөргендә чагында, Щ. өлкәчелек теориясен тәнкыйтьли; Н.Г.Чернышевский, Д.И.Писарев, Г.Т.Бокль һәм позитивистларның идеяләре йогынтысында рус халкы үсешенең тарихи закончалыкларын табигый-фәнни алымнар ярдәмендә тикшерә. Щ. алга сөргән фикерләр тәэсирендә рус тарих фәнендә үз заманы өчен алгарышлы булган, халык тарихына геогр. фактор һәм икътисад йогынтысын тикшерүгә юнәлдерелгән тенденция ярала.

Х е з м.: Сочинения: В 3 т. СПб., 1906–08; Собрание сочинений. Иркутск, 1937.

*Әд.:* А р и с т о в Н.Я. Афанасий Прокофьевич Щапов. СПб., 1883; В у л ь ф с о н Г.Н. Глашатай свободы: Страницы из жизни Афанасия Прокофьевича Щапова. К., 1984.

*Л.М.Айнетдинова.*



А.П. Щапов.



Е.Н. Щеглова.

**ЩЕГЛО́В** Виктор Леонидович (19.7.1948, Казан — 28.7.1997, шунда ук), кинооператор, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986). Бөтенсоюз кинематография ин-тын тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1966 елда Казан телевидение студиясендә башлап җибәрә: кинооператор ассистенты, 1974 тән оператор. Күп еллар дәвамында кинореж. В.И.Беспалов б-н иҗади дуслыкта эшли, аның б-н бергә иҗтимагый танылу алган «Кырлай» (1974, Тбилисида Бөтенсоюз телевизион фильмнар фестивале призы, 1975), «Татарстан — Республикам минем» («Республика моя, Татарстан», 1975), «Яр Чаллы. Шәрехләмәле портрет» («Набережные Челны. Портрет с комментариями», 1979; Бакуда Бөтенсоюз телевизион фильмнар фестивале дипломы, 1979), «Сөюнең сак сүзләре» («Любви негромкие слова», 1983), «Килешү акчадан кыйммәтрәк» («Договор дороже денег», 1984; Киевта Бөтенсоюз телевизион фильмнар фестивале призы, 1985), «Камадагы йорт» («Дом на Каме», 1985) фильмнарын төшерә. Щ. ш.у. «Миллионны нәрсәгә сарыф итәргә» («Как истратить миллион», 1982), «Татлы искергән икмәк» («Этот сладкий чёрствый хлеб», 1984), «Башкарма комитетның гадәти эш көне» («Будни исполкома», 1985), «Минем яшел бишегем» («Зелёная моя колыбель», 1986) фильмнарын төшерә; «Зөя елгасы» («Свияга-река», 1991) фильмының режиссёры һәм операторы.

*Е.П.Алексеева.*

**ЩЕГЛО́ВА** Елена Николаевна (23.3.1968, Куйбышев ш.), балет артисты, педагог, ТРның халык артисты (1995), РФнең атказ. артисты (2003). 1986 елда Пермь хореография уч-щесен (педагог Л.Сахарова), 2009 да Казан консерваториясен тәмамлый. 1986–2009 да Татар опера һәм балет театрының әйдәп баручы солисты, 2009 дан Казан хореография



Е.Н. Щ е г л о в а Китри ролендә («Дон-Кихот» балеты, Л.Минкус). 1994.

уч-щесе педагогы. Төп партияләре: Жизель (шул исем. әсәр буенча, А.Адан), Сильфида (шул исем. әсәр буенча, Х.Левенсхольд), Одетта-Одиллия, Аврора, Маша («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», «Щелкунчик», П.Чайковский), Никия һәм Гамзатти, Китри («Баядерка», «Дон-Кихот», Л.Минкус), Ана бүре («Спартак», А.Хачатурян), Анюта (шул исем. әсәр буенча, В.Гаврилин), Кармен («Кармен-сюита», Р.Щедрин), Сөембикә («Шүрәле», Ф.Яруллин) һ.б. Щ. иҗаты төрле пландагы репертуары, пластик кантиленасы, югары хореографик техникасы, эмоциональ бөтенлеге, рольләрнең сәхнәдә ышандырырлык гәүдәләнеше б-н аерылып тора. Бөтенроссия «Арабеск» балет артистлары конкурсы лауреаты (Пермь ш., 1990).

*В.Н.Горшков.*

**ЩЕЛКУНО́В** Михаил Дмитриевич (25.6.1954, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1992), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2007), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан дәүләт ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлый (1976). 1981 елдан шунда эшли: филос. каф. мөдире (1992 дән), филос. ф-ты деканы (2007 дән), проф. (1993). Бер үк вакытта, 2011 дән, ТР ФАнең социаль-икътисад бүлеге акад.-секретаре. Хезмәтләре фән философиясе, мәгариф, антропология, Казан ун-тында филос. белеме тарихы мәсьәләләренә карый. «Югары һөнәри белем бирүне социаль-психологик тәэмин итүдә методология һәм инновацион технологияләр» хезмәте өчен РФ хөкүмәтенең мәгариф өлкәсендәге бүләгенә лаек була (2012).

Х е з м.: Мировоззрение и общенаучное знание: общенаучные феномены познания в социально-мировоззренческом контексте. К., 1990; Научная рациональность и её роль в развитии общества. К., 1996; Образование в XXI веке: перед лицом новых вызовов. К., 2010 (автордаш).

**ЩЕЛЫВА́НОВ** Евгений Юрьевич (24.4.1956, Будённый р-ны Иске Шәйморза а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011), техник фән. канд. (1985). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1981), шунда ук эшли. 1985 елдан Казан фотоматериаллар ин-тында, баш инженер (2001 дән). 2008 дән «Ласкрафт» ябык АҖ (Казан) инженеры. Хезмәтләре химия технологияләре процессларына һәм аппаратларына карый. Дәүләт бүләге углеводород чималын күкертле кушылмалардан чистарту өчен фталоцианин катализаторларын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ЩЕЛЫВА́НОВ** Юрий Борисович (13.7.1923, Казан — 3.7.2014, Казан), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1977). Татарстанның икееллык партия мәктәбен (1952), Югары партия мәктәбен (Казан, 1960) тәмамлый. 1946 елда «Красная Татария» г-тасында эшли. 1952–56 да Будённый р-нының «Будённовец» г-тасы мөхәррире. 1960 тан «Знамя труда» (Әлмәт ш.) г-тасы мөхәррире урынбасары, 1965–74 тә «Ленинская правда» (Түбән Кама ш.) г-тасы мөхәррире. 1974 тән «Советская Татария» г-тасында: мөхәррир урынбасары, мөхәррир (1978 дән). 1985–98 дә Татарстан аеклык өчен көрәш җәмгыятендә эшли. Мәкаләләре Татарстанның иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни үсеше мәсьәләләренә карый. «Советская Татария» г-тасында һәм «Чаян» ж-лында басылган матур әдәбият әсәрләре, ш.и. хикәяләр, шигырьләр, мәсәлләр авторы. 1980–84 тә ТАССР ЮС депутаты. ТАССР Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. бүләге лауреаты. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Наступление на зло продолжается. К., 1989 (автордаш).

**ЩЕ́ПКИН** Михаил Семёнович (6.11.1788, Курск губ., Обоянь өязе Красное а. — 11.8.1863, Ялта ш.), драма актёры. Рус реалистик театр сәнгатендә сәхнәдә гәүдәләндерелгән персонажның дөреслеккә туры килгән тышкы сурәте б-н рухи дөньясының сәнгатьчә сурәтләнеше үрелеп баруга нигезләнгән «образга керү осталыгы мәктәбе»н оештыручы. Щ.ның замандашы язганча, ул сәхнәгә «үзе гәүдәләндергән затка хас омтылышлар, гадәтләр һәм холык б-н яңадан туган хәлдә» чыга, аның мәнфәгатьләрен «үз мәнфәгатьләрен кайгырткан кебек кайгырта» («Москвитянин», 1841, № 8).

Сәхнә эшчәнлеген граф Г.С.Волькенштейнның крепостной театрында башлап җибәрә. 1822 елда С.Г.Волконский, И.П.Котляревский, В.А.Жуковский ярдәме б-н крепостной бәйлелектән котыла һәм Мәскәүдәге Кече театр сәхнәсендә беренче тапкыр чыгыш ясый, алга таба анда иң зур рольләрен тудыра. 1836 ның сентябрендә Казанга гастрольләр б-н килә, Казан театры сәхнәсендә «Ревизор» (Н.В.Гоголь; провинция сәхнәсендә куйган беренче спектакле) комедиясен куя, бер үк вакытта Городничий ролен башкара. Казанда ш.у. 1838, 1839 һәм 1841 дә дә кызы А.М.Щепкина б-н сәхнәгә чыга: Фамусов («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Арнольф («Хатыннар мәктәбе», Ж.-Б.Мольер), Чупрун, Выборный («Тылсымчы Москаль», «Наталка-полтавка», И.П.Котляревский), Симон («Матрос», Т.Соваж, Ж.-Ж.Делюрье), Репейкин



М.С.Щепкин кызы А.М.Щепкина белән Казан сәхнәсендә куелган «Матрос» (Т.Соваж, Ж.-Ж.Делюрье) спектаклендә. К.А.Данненберг рәсеме.

(«Кайгыртучы», А.И.Писарев), Ижорский («Рославлев», М.Н.Загоскин) рольләрен башкара. Щ.ның Казан труппасы б-н чыгышлары Казанның театр тормышында зур вакыйга була, Казан актёрларының проф. осталыгына һәм театрның алга таба үсешенә зур йогынты ясый.



М.С.Щепкин.

*Әд.:* К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958; Б л а г о в Ю. «В Казани мне было очень хорошо...»: Гастроли М.С.Щепкина // Казань. 2006. № 3.

*Ю.А.Благов.*

**ЩЕПОВСКИ́Х** Анатолий Иванович (15.1.1945, Оренбург өлкәсенең Бозаулык р-ны Сухоречка а. — 4.9.2013, Казан), хуҗалык-хакимият эшлеклесе, геогр. фән. канд. (1999), РФнең атказ. экологы (2009). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын (1974), Саратов югары партия мәктәбен (1981) тәмамлый. 1963–64 елларда Оренбург өлкәсенең Тримихайловская урта мәктәбендә укыта. 1967–68 дә ВЛКСМның Бозаулык шәһәр ком-ты инструкторы, 1968–74 тә КПССның Лениногорск шәһәр ком-ты инструкторы, 1974–76 да партия комиссиясе рәисе. 1976–82 дә халык депутатларының Лениногорск шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары. 1982–92 дә рәисе. 1992–93 тә халык депутатларының Лениногорск шәһәр советы рәисе. 1993–2001 дә ТР әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министры. 2001–10 да ТР экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары. 2010 нан Түбән Кама муниципаль р-ны башлыгы киңәшчесе. Хезмәтләре табигый байлыкларны куллану б-н идарә итү мәсьәләләренә, әйләнә-тирәдәге мохитне саклауга карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Совершенствование региональных систем управления природопользованием. М., 1997; Современные проблемы охраны атмосферного воздуха. К., 1997; Природопользование и охрана окружающей среды: федеральные, региональные и муниципальные аспекты. К., 1999.

*Е.Б.Долгов.*

**ЩЕРБАКО́В** Арсений Яковлевич (16.8.1839, Казан губ., Лаеш өязе Шомбыт а. — 9.3.1900, Казан), биохимик, медицина д-ры (1865). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый (1961). 1862–63 елларда Берлин, Дерптта чит ил командировкасында була. 1864–94 тә Казан ун-тында эшли: 1871 дән мед. химиясе һәм физика каф. (1884 тән мед. химиясе кафедрасы) профессоры һәм мөдире, бер үк вакытта, 1886–90 да, мед. ф-ты деканы, 1887–89 да еш кына вакытлыча ректорны алмаштыра. Хезмәтләре земство медицинасына, кан биохимиясенә, Казанда су б-н тәэмин ителеш мәсьәләләренә карый. «Физиологик химия курсы. 1 нче кисәк» («Курс физиологической химии. Ч.1», 1893) кулланмасы авторы. Казан табибләр җәмгыяте рәисе, 1899 дан аның шәрәфле әгъзасы. Казан ун-ты каршында Табигыятьчеләр җәмгыятен нигезләүчеләрнең

берсе (1869). Гомеренең соңгы 3 елында Казан шәһәр думасы гласные, шәһәр идарәсе әгъзасы һәм шәһәр башлыгы урынбасары була.

Х е з м.: Температура почвы, углекислота и влажность почвенного воздуха, уровень почвенной воды, анализ вод. К., 1875; Свойства воды, употребляемой для питья в городе Казани. СПб., 1876; Источники водоснабжения г.Казани. К., 1893; Питание и пища человека и животных. К., 1899.

*Әд.:* З у б а и р о в Д.М. 125-летие основания первой кафедры медицинской химии и физики в России // Казан. мед. журн. 1987. № 3.

**ЩЕРБАКО́В** Геннадий Иванович (27.3.1941, Воронеж ш.), радио электроникасы өлкәсе галиме, техник фән. канд. (1971), проф. (1994), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2003). 1964 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, радио техникасы ф-ты деканы (1987–2003), радио идарәсе каф. мөдире (1990 нан), Радио электроникасы һәм телекоммуникацияләр ин-ты директоры (2003 тән). Хезмәтләре антенналар теориясе һәм техникасына: бирелгән характеристикалар буенча антенна системаларын синтезлау, телекоммуникация корылмаларын һәм системаларын оптимизацияләүгә карый. Щ. мәктәп-көллият-югары уку йорты комплексы базасында өзлексез интеграль һөнәри белем бирү системасын эшли. СССР мактаулы радисты (1982).

Х е з м.: Оптимальное решение задач теории синтеза антенн // Радиотехника и электроника. 1969. Т. 14, № 7 (автордаш); Передача сигналов многоканальных измерительных систем по кабельным телевизионным сетям // Измерительная техника. 1994. № 4; Пути организации непрерывного образования в условиях профессиональной школы // Вестн. Казан. техн. ун-та. 1996. Вып. 2 (автордаш).

**ЩЕРБАКО́ВО** авылы, Казан шәһәренең Авиатөзелеш р-ны составында, Биектау тимер юл станциясеннән 10 *км* көнбатыштарак, Казансу елгасы буенда. 16 йөз ахырыннан Щербаково Пүчинкәсе буларак билгеле. Халкы сарай (1797 дән — удел) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 20 йөз башында Щ.да ярма з-ды, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 385 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Каймар волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Биектау р-нында, 1998 нең 27 ноябреннән Казан шәһәренең Авиатөзелеш р-ны карамагында. Халык саны: 1646 да — 48, 1782 дә — 65 ир-ат; 1859 да — 156, 1897 дә — 166, 1908 дә — 189, 1920 дә — 190, 1926 да — 226, 1938 дә — 225, 1949 да — 300, 1958 дә — 204, 1970 тә — 185, 1989 да — 39 кеше.

**ЩЕРБАТЕ́НКО** Лидия Александровна (4.9.1923, Әрмәнстан ССР, Ереван), кардиолог, мед. фән. д-ры (1971), проф. (1973). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1946), шунда ук факультет терапиясе кафедрасында эшли. 1951–2004 елларда Казан ГИДУВының 1 нче терапия кафедрасында, 1974–87 дә каф. мөдире, 1988 дән проф.-консультант. Хезмәтләре миокард инфарктына, йөрәк ишемиясенә башлангыч чорда диагноз куюга карый. ТАССР кардиологлар җәмгыяте рәисе (1972–92).

Х е з м.: Коматозные состояния. М., 1956; Внутрикамерные разрывы сердца в клинике острого инфаркта миокарда // Патология сердечно-сосудистой системы: Сб. статей. Минск, 1979.

**ЩЕРБАТЕ́НКО** Сергей Иванович (5.10.1918, Курск өлкәсенең Старый Оскол р-ны Салтыково а. — 25.3.2003, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1977), ТАССРның атказ. табибе (1967). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1941), Мед. ин-ты клиникалары идарәсе каршында табиб-диетолог булып эшли. 1944 елдан факультет терапиясе клиникасы табибе, 1945–64 тә факультет терапиясе кафедрасында, бер үк вакытта, 1953–57 дә, дәвалау ф-ты деканы урынбасары, 1964–86 да Казан мед. ин-тының 2 нче госпиталь терапиясе каф. мөдире. Хезмәтләре ревматизмга диагноз кую һәм дәвалауга карый. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лечение ревматоидного артрита // Казан. мед. журн. 1962. № 5; Применение некоторых иммунологических методов для выявления специфического антигена в лейкоцитах больных лейкозом // Вопр. вирусологии. 1975. № 4 (автордаш).

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997; Б о г о я в л е н с к и й В.Ф., З у б а и р о в Д.М. Профессор Сергей Иванович Щербатенко: Некролог // Казан. мед. журн. 2002. № 3.

**ЩЕТИ́НКИН** Павел Васильевич (2.11.1845, Казан — 1918), Казан сәүдәгәре һәм эшмәкәре, хәйрияче, хакыйкый статский советник (1911), нәселдән килүче мактаулы гражданин. Казан мех ф-касы, Воскресенская урамында йорт җиһазлары һәм парча товарлары кибете, Георгиевская урамында 2 катлы таш йорт, Казан губернасының Лаеш өязе Урта Девятово авылындагы утар һәм ат з-ды хуҗасы. 1889 елдан шәһәрнең иң зур кунакханәсе «*Казанское подворье*» аның милкендә була. 1902 дә Щ. кунакханәгә терәлеп торган бинаны (Проломная б-н Петропавловская урамнары чаты) сатып ала һәм, арх. Л.Хрщонович проекты буенча кунакханәгә өстәп, 4 нче катны төзетә, фасадны тулысынча үзгәрттерә һәм, ике бинаны да өлешчә яңадан планлаштырып, аларны берләштерә. «П.В.Щетинкин Казанда» («П.В.Щетинкин в Казани») сәүдә-сәнәгать ширкәтен оештыра, аның фирмасы күп кенә ярминкәләрдә уңышлы сәүдә итә; Казан, Самара, Сембердә кибетләре ачыла. 1879–1917 дә Казан шәһәр думасы гласные. Казан үзәк керәшен татар мәктәбе попечителе (1871 дән), Император Кеше сөю җәмгыяте (1878 дән) әгъзасы, Рухани ведомство карамагындагы ир-атлар һәм хатын-кызлар уч-щеләре, ш.у. Казан руханилар академиясе шәрәфле күзәтчесе (1875 тән). Казанда Николо-Низский чиркәве, Казан үзәк керәшен татар мәктәбе каршындагы хастаханә, Смолдеярово, Янсуар, Сукуры, Югары Әрнәш, Кавал, Шомырбаш авылларында чиркәүләр һәм мәктәпләр төзелешенә, Казан



П.В. Щетинкин.

ир-атлар һәм хатын-кызлар рухани уч-щеләре хаҗәтләренә акча иганә кыла. Беренче бөтендөнья сугышы елларында Казан биржа җәмгыятенә госпиталь өчен Георгиевская урамындагы йортында 70 яралыны сыйдырырлык урын бирә. 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Владимир орденнары, Станислав һәм Анна тасмалары булган алтын медальләр, Кавказда христианлык торгызу җәмгыятенең 4 нче дәрәҗә билгесе, Корабль һәлакәтенә дучар булганнарга ярдәм итү җәмгыятенең көмеш билгесе б-н бүләкләнә.

**ЩЕТИ́НКИН НО́МЕРЛАРЫ**, к. «*Казанское подворье*».

**ЩЁКИНО РАЙОНЫ́**, Тула өлкәсенең үзәгендә урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 1,3 мең *км*². Үзәге — Щёкино шәһәре (Туладан 22 *км* ераклыкта). Халкы — 106384 кеше (2017). Татарлар саны: 2010 елда — 442 кеше. Татарлар, күпләп, ул җирләргә 1930 елларда күчеп киләләр, таралып яшиләр.

**ЩЁЛКОВ** Фёдор Лазаревич (12.7. 1948, Куйбышев өлкәсенең Клявлинский р-ны Балахановка а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002), ТРның атказ. нефтьчесе (1994). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1972). 1966 елдан (бүленеп) «Татнефть» АҖдә: «Татбурнефть» трестында бораулаучы ярдәмчесе (1969 га кадәр), өлкән механик, җитештерүдә хезмәт күрсәтү базасы башлыгы урынбасары, башлыгы. Лениногорск бораулау эшләре идарәсендә партком секретаре, Лениногорск пластларның нефть бирүчәнлеге һәм скважиналарны капиталь ремонтлау идарәсе башлыгы (1983–85), АҖнең ген. директоры урынбасары (1987 дән). Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге экологик чиста технологияләрне эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә, тузган вакланмаган шиннарны утильләштерү өчен комплекслы-модульле җайланмаларны сәнәгатьтә җитештерүне оештыруда катнашканы өчен бирелә. Халыклар дуслыгы ордены, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ЩИПАЧЁВ** Борис Иванович (1.1.1945, Кемерово өлкәсенең Анжеро-Судженск ш. — 25.2.2006, Казан), технолог, техник фән. д-ры (1997), ТАССРның атказ. машина төзүчесе (1988), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1989). Томск ун-тын тәмамлый (1967), Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли: лаб., бүлек башлыгы, баш конструктор, 1998 елдан директор урынбасары. Хезмәтләре эчке баллистикага һәм махсус эшләнмәләр конструкцияләүгә карый. Щ. җимерелүче сүрүләрдә ялкынландыргыч җайланмаларны проектлау методикасын эшли. Югары энергетикалы дары кулланылган

хәлдә атышның закончалыклы процессын тәэмин итү өчен камера эче механизмнарын тикшерә. 200 дән артык фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 64 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**ЩИРА́** (Җирә) елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Норма елгасының (Мишә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 13 *км*. Бассейнының мәйданы 56 *км*². Елга башы Арча р-ны Кызыл Сарай посёлогыннан (даими яшәүчеләр юк) төньяктарак «Ленин дачасы» урман массивында, тамагы Питрәч р-ны Белкино авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 82 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Щ.ның 2,4 һәм 2,7 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Озак вакыт яңгырлар булмаганда Щ. һәм аның кушылдыкларының аерым урыннары кибә. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 *м*³/*с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Щ. бассейнында суының гомуми күләме 0,95 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ЩУ́КИН** Андрей Викторович (7.7.1950, Казан), җылылык энергетигы, техник фән. д-ры (1991), проф. (1993), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2001). 1973 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, газ турбиналы, пар турбиналы корылмалар һәм моторлар каф. мөдире (1992 дән). Хезмәтләре газ пәрдәләрен фундаменталь һәм гамәли тикшерүләр өлкәсенә карый. Щ. югары температуралы газтурбиналы моторлар өчен дискрет-саркучан диварчыкларны хисаплап чыгару, катлаулы чикләнеш шартларында җылы алмашуның диварчык яны интенсивлашуы алымнарын эшли. Югары басымлы турбинаның сопло аппаратын һәм авиация моторы газҗыйгычын һава б-н суытуның интенсивлаштырылган системаларын эшләүдә һәм стендта сынауда катнаша. Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2008).

Х е з м.: Теплопередача в охлаждаемых деталях газотурбинных двигателей. М., 1993 (автордаш); Интенсификация теплообмена сферическими выемками при воздействии возмущающих факторов. К., 2003 (автордаш).

**ЩУ́КИН** Виктор Константинович (3.11.1921, Чита өлкәсенең Петровск-Забайкальский ш. — 15.4.2001, Казан), моторлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1968), проф. (1969), ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1972,1980), Казан техник ун-ты атказ. профессоры (1997). 1944 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, җылылык техникасы каф. мөдире (1964–89), каф. профессоры (1989 дан). Хезмәтләре инерцияле масса көче кырларындагы җылылык массасы алмашуына һәм агымнар гидродинамикасына карый. Щ. инерцион масса көчләре тәэсирендәге кайнар сыекча агымнарындагы җылылык алмашуга һәм гидравлик каршылыкны хисаплау өчен матем. модельләр эшли. Уйлап табуга 37 авторлык таныклыгы бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Рабочие процессы в жидкостных реактивных двигателях. М., 1953 (автордаш); Термодинамика и теплопередача. М., 1991 (автордаш); Теория и техника теплофизического эксперимента. М., 1993 (автордаш).

# Ы

**ЫК** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Кама елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 436 *км*, ТР чикләрендә 120 *км*. Бассейнының мәйданы 14990 $км^2$. Елга башы һәм югары агымы Башкортстан Респ-касында; якынча 200 *км* озынлыкта Татарстан һәм Башкортстан чикләре буйлап ага; Нугайбәк авылыннан төньяктарак — ТР терр-ясеннән Мөслим һәм Минзәлә р-ннарында ага. Түбән Кама сусаклагычы төзелгәнче, Ы. Менделеев р-ны Ык Тамагы авылына каршы Кама елгасына коя. Хәзер елганың Минзәлә р-ны Бикбау авылыннан түбәндәрәк ятучы участогы су астында. Елга башының абс. биеклеге 338 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу мәйданы — кушылдыкларының тирән үзәннәре б-н аерым платоларга (сыртлар) бүлгәләнгән калкулык. Ы.ның үзәне асимметрияле. Текә уңъяк сөзәклекләренең кайбер урыннарында денудациягә аеруча чыдам токымнарның чыгышлары б-н бәйле структур террасалар ачык күренеп тора. Калдык таулар, калкулык һәм тау тезмәләре урыны-урыны б-н елга үзәннәре сызыгын кискәли; рельефның бүрәнкә рәвешендәге карст формалары билгеләнә (киңлеге 80 *м* га кадәр, тирәнлеге 2–6 *м*). Сулъяк яр буйлап аллювиаль террасалар комплексы: тугай һәм 3 тугай өсте террасасы сузыла. Тугай террасасы 2 яссылыкта. Беренче яссылык — киңлеге 50 *м* га кадәр булган хәзерге тугай; урыны б-н сазлыклы, түбән агымында элеккеге елга юлында сакланып калган күлләр күп. Икенче яссылык — биеклеге 1,7–3 *м*, киңлеге 1,5 *км* га кадәр булган югары тугай. Беренче тугай өсте террасасы барлык урында үсеш алган, аның биеклеге 4–7 *м*, киңлеге 1,5–2 *км* га кадәр. Икенче һәм өченче тугай өсте террасалары кайбер урыннарда гына очрыйлар. Ы.ның юлы бормалы, күп санлы меандралар нәтиҗәсендә катлауланган (аеруча түбән агымда); киңлеге 80 *м* га кадәр, ике сайлык арасындагы тирән сулы урыннарда 2–3 *м*, сайлыкларда — 0,5 *м* га кадәр. Ы.ның 91 кушылдыгы бар, ТРдагы иң зурлары: Минзәлә (159 *км*), Дим (85,7 *км*), Мәллә (71,6 *км*), Кандыз (64,2 *км*), Югары Кандыз (59,7 *км*), Эстәрле (53,3 *км*), Ютазы (45,2км) — сул кушылдыклар; Бәҗәнә (35,1 *км*), Мөшеге (29,5 *км*), Казанчы (20 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,46 $км/км^2$. Елганың туенуы катнаш, җәен — тотрыклы рәвештә җир асты сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле югары агымында 5–10 $л/с{\cdot}км^2$ дан түбән агымында 0,1 $л/с{\cdot}км^2$ га кадәр.

Елга режимын күзәтү эшләре 1931 елдан Нугайбәк авылы янындагы (Башкортстан Респ-касы) гидрологик постта алып барыла. Биеклекнең уртача еллык тирбәнешләре 3,6 *км* (макс. 5,2 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 97–140 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 60–70 *мм*. Язгы ташу (уртача 30–50 көн дәвам итә), гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана, су биеклегенең тиз арада күтәрелүе һәм тиз төшүе б-н сыйфатлана. Суның иң зур чыгымы 3610 $м^3/с$ (1974). Җәен су биеклеге тотрыклы, кайбер вакытта яңгыр ташкыннары б-н үзгәрә. Бассейнда еллык ташкын агымы катламы 1,5–3 *мм*. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 25,3 $м^3/с$. Ы., гадәттә, ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Боз кату тотрыклы, уртача 140–150 көн дәвам итә. Кыш ахырына бозның калынлыгы 60–90 *см* га (макс. 185 *см*) җитә. Нугайбәк



Ык елгасы түбән агымында.

авылы янында суының уртача еллык чыгымы 45,7 $м^3/с$. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 26 $м^3/с$. Китерелмәләрнең уртача еллык күләме 240 мең *т*. Суның төп агым буенча уртача болганчыклылыгы 150 $г/м^3$. Елга суы химик составы буенча, нигездә, гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1200 *мг/л*, Ютазы елгасы тамагыннан түбәндәрәк (Япрак авылы тирәсендә) — 6000 *мг/л* га кадәр. Елга нефть чыгару һәм нефть эшкәртү пр-тиеләре агымнары б-н пычрана. Ы. бассейнында суының гомуми күләме 78,9 млн. $м^3$ булган 96 буа бар. Су ресурслары сугару, сәнәгать һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла. Елга ТРның табигать истәлеге (1978). Аның бассейнында аеруча сакланулы табигать терр-яләре: Чатыр Тау, Салих тавы, Спас чишмәләре, Петровка наратлары, Татар Димескәе аланы, Игим наратлыгы, Наратасты урманы, Урдалы Тау урнашкан.

**ЫК** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 18 *км* көнбатыштарак, Ютазы елгасы буенда. 2010 елда 115 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. 1920 елларның 1 нче яртысында нигез салына. Башта ТАССРның Бөгелмә кантоны Бәйрәкә волостена керә, 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1926 да — 55, 1938 дә — 240, 1949 да — 142, 1958 дә — 103, 1970 тә — 66, 1979 да — 36, 1989 да — 89, 2002 дә — 117 кеше.

**ЫК ТАМАГЫ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 20 *км* көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 65 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский исеме б-н дә билгеле. 1764 кә кадәр Ы.Т. Кострома Богоявление монастырена карый. 1764 тә халкы — экономик, 1841 дә дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, балык тоту б-н шөгыльләнә, Пермь губернасына китеп эшли. 18 йөздән Ы.Т. эре ашлык сату үзәге булып китә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, анда аракы з-ды, пристань, 20 йөз башында чиркәү, земство мәктәбе (1896 да ачыла), китапханә (1901 дән), селитра з-ды була; дүшәмбе базары эшли. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Кураково волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1795 тә — 365 ир-ат; 1859 да — 832, 1887 дә — 848, 1892 дә — 975, 1920 дә — 1120, 1926 да — 1241, 1938 дә — 944, 1949 да — 838, 1958 дә — 583, 1970 тә — 338, 1979 да — 182, 1989 да — 92, 2002 дә — 88 кеше.

**ЫЛЫСЛЫ́ АГАЧЛА́Р УРМАНЫ́**. Башлыча, Төньяк ярымшарда таралган. Караңгы ылыслы, якты ылыслы һәм *катнаш урманнарга* аерыла. Караңгы ылыслы урманнар (К.ы.у.) чыршы, ак чыршы, эрбет наратларыннан (эрбет) тора. Аларның куе ябалдашлары, агачларның нык кысылганлыгы яктылыкның аз булуына, урманның аскы ярусы һәм туфракның начар җылынуына китерә. Шунлыктан К.ы.у.да куаклык һәм тере туфрак өсте капламы күләгәгә чыдам үсемлекләрдән (яшел мүкләр, кара җиләк, кымызлык һ.б.) тора, ә туфрак өслегендә, гадәттә, калын урман түшәлмәсе барлыкка килә. Чыршылыклар тайга зонасы табигатен хәтерләтә, чыршы, кайвакыт Себер акчыршысы һәм аз гына яфраклы токымнар катнашкан утыртылмалар хасил итә. Балчыксыл һәм комсу, чагыштырмача 1,5–2 *м* һәм тирәндәрәк яту-

чы грунт сулы кәсле туфракларда үсәләр. ТРда урыны б-н Себер акчыршысы катнашындагы караңгы ылыслы чыршы утыртмалары, Кама алдындагы катнаш урманнар зонасында, Пермь системасы карбонат токымнарындагы уңдырышлы туфраклы тау битләрен һәм субүләр платоны били. Өстенлекле урман типлары чыршылыклар һәм катлаулы акчыршылыклар — юкәле, сирәк кенә — чикләвек куаклы һәм имәнле, ш.у. чыршылык-яшел мүклеләрдән гыйбарәт. Элек К.ы.у. Кама алдының төньяк өлешендә өстенлек итүче формация була. Әмма Бөек Ватан сугышы елларында һәм сугыштан соңгы чорда зур күләмдә кисү эшләре бара, 1966 елга аларның мәйданы 17,3 мең *га* га кадәр кими һәм урман б-н капланган мәйданның бары тик 1,8%ын гына тәшкил итә. 1970 елларда респ-када чыршылыклар утырту башлана,



Ылыслы агачлар урманы. Саба урманчылыгы.

2000 еллар ахырына аларның мәйданы 78 мең *га* (6,8%) тәшкил итә. К.ы.у. — мөһим чимал базасы. Чыршы үзагачы — целлюлоза-кәгазь сәнәгате, агач материаллары, төзелеш агачы өчен төп чимал.

Якты ылыслы урманнар (Я.ы.у.) яктылык яратучы ылыслы токымнардан: нарат һәм карагайдан тора. Ябалдашының сирәк ботаклы булуы һәм агачларның чагыштырмача тыгыз урнашмавы сәбәпле явым-төшемнәр һәм җылылык туфрак өслегенә күбрәк үтеп керә. Куе куаклык һәм тере туфрак өслеге капламының (кара җиләк, нарат җиләге, яшел мүкләр, энҗе чәчәк, лишайниклар һ.б.) бай булуы хас. Я.ы.у. тигезлектә, тауларда, сазлык һәм комнарда үсәләр, тундрадан дала зонасына кадәр киң геогр. һәм эдафик диапазонларга ия. ТРда Я.ы.у.ның мәйданы 190,1 мең *га* (урман б-н капланган мәйданның 16,8%ы), ш.и. нарат урманнары — 185,7 мең *га*, карагай урманнары — 5,4 мең *га*. Табигый наратлыклар Идел, Кама, Вятка, Мишә, Казансу елга террасаларының комлы һәм комсу туфракларында үсә. Аеруча лишайник-мүкле, мүкле, куаклы, юкәле, чикләвек куаклы, өрәңгеле наратлыклар таралган. ТРның барлык урманчылыкларындагы урманнарда нарат һәм карагай культуралары бар. Наратлыклар һәм карагай урманнары югары продуктивлыкка ия, 1–1а бонитет классы агачлар өстенлек итә. Я.ы.у. саклагыч һәм сан.-гигиена функциясен башкаралар, яхшы физик-механик үзлекләргә ия эш агачы алу чыганагы булып торалар.

*Ә.Һ.Газизуллин.*

**ЫЛЫЯ́**(Уткино) авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 31 *км* төньяктарак, Юкәче елгасы буенда. 2010 елда 56 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда По речке Лые, Уткина Лыя исемнәре б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында тегермән, 1 йон-тукыма ману һәм 2 май язу йорты, 1 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 511,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 57 ир-ат; 1859 да — 325, 1897 дә — 476, 1908 дә — 439, 1920 дә — 520, 1926 да — 519, 1949 да — 370, 1958 дә — 306, 1970 тә — 324, 1979 да — 255, 1989 да — 134, 2002 дә — 93 кеше.

**ЫМЛЫ́К**, сөйләүченең хис-тойгыларын, эчке кичерешләрен, теләк-ихтыярын белдерүче төрләнми торган сүз төркеме. Атау функциясенә ия түгел, җөмлә кисәге булып килә алмый; интонация, ишарә, мимика б-н тыгыз бәйләнештә. Татар телендә ясалышы буенча Ы.лар ике төргә бүленә: 1) төп Ы.лар — аларга төрле авазлардан яки аваз җыелмаларыннан гына торган, башка сүз төркемнәре б-н бәйләнмәгән Ы.лар керә: а, ә, и, ай, әй, их, һе, һи, ай-һай, абау, әбәү һ.б.; 2) ясалма Ы.лар — башка сүз төркемнәреннән (пәрәмәч, менәтерәк), фразеологизмнардан (йөзе кара булгыры, шайтан алгыры), алынма сүзләрдән (ура, браво, билләһи) барлыкка килә. Кайбер Ы.лар татар телендә сирәк очрый торган яки гадәти булмаган авазлардан һәм авазлар тезмәсеннән ясала: трр, тсс, тфү. Төзелешләре ягыннан төп Ы.ларны 3 төркемгә бүлеп өйрәнәләр: ялгызак (а, абау, әбәү, ай, ах, әх, һай һ.б.), куш (ай-ай, һай-һай, уф-уф һ.б.), парлы (ай-вай, ай-яй, ах-ваһ һ.б.) Ы.лар.

Составы ягыннан ясалма Ы.лар гади, кушма һәм тезмә булырга мөмкин. Гади Ы.лар бер нигездән генә тора: бәлеш, тамаша, ходаем һ.б. Кушма Ы.лар сүзләр кушылу ысулы б-н ясала: нихәл, әттәгенәсе һ.б. Тезмә Ы.ларга ирекле сүзтезмәләрдән (шул-шул менә, менә тагын һ.б.), ш.у. фразеологизмнардан (рәхмәт төшкере, чәнчелеп киткере һ.б.) ясалган Ы.лар керә. Мәгънә ягыннан эмоциональ һәм императив Ы.лар була. Күпчелек эмоциональ Ы.лар күп мәгънәле булулары б-н аерылып тора, мәс., а, ай, и, их, ух, әх, әй, абау, әбәү һ.б. Интонациядән һәм контексттан чыгып, бу Ы.лар төрле мәгънә белдерергә мөмкин: соклану, гаҗәпләнү, шатлану, танып алу, үкенү, шөбһәләнү, ачулану һ.б. Гадәттә, Аллаһка мөрәҗәгать итү сүзләре дә эмоциональ Ы.лар составында карала: ай Аллам, әй Раббым, Илаһым Раббым һ.б. Императив Ы.лар ихтыярны, чакыру, өндәү яки әйдәү кебек мәгънәләрне белдерә: ау (чакыру), каравыл (курку) һ.б. Ы.ларның аерым төркемен сөйләм этикетына кергән, көндәлек тормышта еш кулланыла торган үзенчәлекле сүзләр тәшкил итә: нихәл, исәнме, сау бул, гафу итегез, рәхим итегез һ.б.

*Әд.:* Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; Татар грамматикасы. К., 2016. Т. 2.

**ЫРГА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Әшнәк елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 13,7 *км*, бассейнының мәйданы 45,9 $км^2$. Балык Бистәсе р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Ырга авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Корноухово авылыннан көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 66 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Ы.ның 0,2 дән 1,9 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,45 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,51–1 $л/с \cdot км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елганың югары агымы суының иң аз вакытында кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 137 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,027 $м^3/с$. Язын суы каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Ы. бассейнында суының гомуми күләме 1,2 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ЫРГАКБАШЛА́Р** (Acanthocephala), эндопаразит суалчаннар классы. 500 дән артык төре билгеле. Умырткалы хайваннарның эчәклегендә, личинкалары — умырткасызлар (кысласыманнар һәм бөҗәкләр), кайвакыт вак имезүчеләр тәнендә яши. Гәүдәсе капчыксыман, озынлыгы 1 дән 65 *см* га кадәр. Гәүдәсенең очында хәрәкәтчән хортумчык, анда күп кенә кечкенә ыргаклар урнашкан. Тире-мускул капчыгы катлаулы төзелешле (кутикула, субкутикуляр катлау, гиподерма, боҗра һәм арткы буй мускуллар). Азыкны тәненең бөтен өслеге б-н суырып осматик юл б-н туена (мембраналы туену). Бүлеп чыгару системасы протонефридиаль типта. Нерв системасы хортумлы җиңсә эчендә урнашкан шарсыман яки озынча түгәрәк ганглийдан тора. Аерым җенеслеләр, күкәй салучылар. Ы. паразитлыгыннан балык һәм кошлар, аеруча үрдәк кошлар зыян күрә. Акантоцефалёз авыруын тараталар. Кешегә зыяны тигән очраклар да билгеле.

*О.Д.Любарская.*

**ЫРЫ́М** елгасы, Идел алдында, Гөбенә елгасының сул кушылдыгы (Зөя елгасы бассейны). Озынлыгы 45,1 *км*, ТР чикләрендә — 14 *км*. Бассейнының мәйданы 248,6 $км^2$. Идел буе калкулыгыннан ага. Елга башы Чуаш Респ-касы терр-ясендә, тамагы Кайбыч р-ны Мәлки авылыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. Ы.ның 0,3 тән 5,6 *км* га кадәр озынлыктагы 29 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк.Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 91 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 86 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Ы. ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,04 $м^3/с$. Суы ел буе чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**ЫРЫ́М**, к. *Урюм*.

**ЫРЫНГЫ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 8 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасы буенда. 2010 елда 842 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Кирпеч з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1640 елларда нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче чирегендә халкы — дәүләт, 1835 — 1860 елларда удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; чиркәү, земство мәктәбе, 15 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1024,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырынгы волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 624, 1859 да — 533, 1897 дә — 1195, 1913 тә — 1326, 1920 дә — 1193, 1926 да — 1086, 1938 дә — 1125, 1949 да — 991, 1958 дә — 964, 1970 тә — 1168, 1979 да — 1133, 1989 да — 831, 2002 дә — 867 кеше.

**ЫРЫ́С**, к. *Урыс*.

**ЫРЫ́С БӘК** (? – 1590), Олы Нугай Урдасы бәге (идарәчесе) (1578 елдан). *Исмәгыйль бәк* улы. Тышкы сәясәттә Кырым ханлыгы һәм Рус дәүләте арасында җайлашырга омтыла. Ы.б.кә Мәскәү яклы нугай аксөякләренең бер өлеше (*Ырыс Мөхәммәд бәк* һ.б.) каршы була. Ы.б. үлгәннән соң, хакимияткә Ырыс Мөхәммәд бәк килә.

*Әд.:* Трепавлов В.В. История Ногайской Орды. М., 2002.

**ЫРЫ́С МӨХӘММӘ́Д БӘК** (? – 1597/98), Олы Нугай Урдасы бәге (идарәчесе) (1590 елдан). *Динәхмәд* бәк улы. Мәскәү тарафдары. Нугай аксөякләре арасында тарафдарлары була. Себер ханлыгы таркалганнан соң, «Тайбуга җирәбәсе» уделына ия була һәм тайбуга дәрәҗәсе ала (1580 еллар башында). Хакимияткә *Ырыс бәктән* соң килә, аның уллары б-н көрәштә һәлак була.

*Әд.:* Трепавлов В.В. История Ногайской Орды. М., 2002.

**ЫРЫ́С МӨХӘММӘ́Д ХАН** (1330 тирәсе – 1376), Күк Урда идарәчесе (1360 еллар уртасыннан). *Чимтай бәк* улы. Атасы үлгәннән соң тәхеткә утыра. Үзәк хакимиятне ныгыту сәясәте алып бара. 1364–67 дә *Газиз шәех хан* ягында торып *Мамай* әмиргә каршы сугыша. Сыгнак шәһәрендә акча суктыра (1370–71). 1375 тә Хаҗитархан шәһәренә уңышсыз яу чаба. Ы.М.х. ның эчке сәясәте аксөякләрдә канәгатьсезлек тудыра. Ы.М.х.га каршы көрәшкә Урта Азия идарәчесе *Аксак Тимер* булышлыгы б-н *Туктамыш* (Ы.М.х. тарафыннан җәзалап үтерелгән Туйхуҗа угланның улы) җитәкчелек итә. Туктамыш б-н үзара сугыш вакытында үлә.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

*И.Л.Измайлов.*

**ЫСЫЛДАВЫ́К КОШ** (Jynx torquilla), тукран кошлар семьялыгындагы кош. Европа, Азия һәм Африкада (фәкать үзәк өлештә) таралган. Күчмә кош. ТР терр-ясенә апрельдә килә. Катнаш һәм киң яфраклы урманнарда, бакча һәм паркларда яши. Гәүдәсенең озынлыгы 20 *см* тирәсе, авырлыгы 25–40 *г*. Каурый капламы кара-көрән бизәкле җирән-соры төстә. Тукран кошлар семьялыгындагы



башка кошлардан аермалы буларак, кайры һәм үзагачны чокырга сәләтле көчле томшыклы түгел, койрыгында каты терәк каурыйлары да юк. Теленең очы төкчәләрсез. Оясын агач куышларында кора. Якынча тонык ак төстәге 11 йомырка сала. Кырмыска, гөбләләр һ.б. бөҗәкләр б-н туклана, аларны ябышкак төкерек б-н чылатылган озын теле ярдәмендә таба. Оясына якын килүче дошманнарны куркыту өчен башын боргалый һәм елан ысылдавына охшаш тавыш чыгара (исеме шуннан).

*Әд.:* Попов В.А., Лукин А.В. Животный мир Татарии. К., 1988.

**ЫШАНУЛА́Р**, фольклор жанры төре. Кыска афористик формада тегеяки бу хәлләрнең нәтиҗәләре турында фаразлаулары чагылдыра. Багуга һәм *сынамышка* якын. Эчтәлеге ягыннан татар Ы.лары берничә төркемгә бүленә, алар: 1) архаик гореф-гадәтләргә, йолаларга барып тоташалар; 2) мәҗүсилек һәм мөселман мифологиясенә барып тоташалар; 3) татар халкының көндәлек тормышын һәм әхлакый кыйммәтләр системасын чагылдыралар. Корбан чалу архаик йоласы, мәс., көтү башында алда кызыл сыер кайтса, көн кояшлы булыр, ә кара сыер кайтса — яңгыр булыр дигән Ы.га барып тоташа. Борынгы заманда кояшлы көн сорап дога кылганда — кызыл сыерны, ә яңгырлы көн сораганда — кара сыерны корбанга китергәннәр. Тимернең сихри көче турындагы Ы. мәҗүсилек мифологиясенә барып тоташа: «Боз яуганда тәрәзә аша тимер ташласаң, боз явудан туктый». Яшен аткан шайтаннар турындагы Ы.да мөселман мифологиясендәге кузаллаулар убыр, су анасы, Албасты кебек мәҗүси образлар б-н үрелеп киткәннәр: «Яшен суккан шайтан урманга төшсә — су анасы, җиргә төшсә — албасты була, ди». «Йөкле вакытта хатын-кыз алма ашаса, баласы матур була» дигән Ы.да ана кешегә хөрмәт, ихтирам б-н карау, йөкле хатын-кызга гаиләдәге иң яхшы әйберләрне генә бирергә кирәк дигән татар аңына хас күренешләр чагыла. «Кулы каты егет карт хатын ала, имеш» дигән Ы.да — көчле һәм эчкерсез ир кеше идеалы, капма-каршысы очраганда бәхет булмауны фаразлау чагыла.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. К., 1987; Ышанулар // Татар халык иҗаты: Хрестоматия. К., 2005; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«ЫШАНЫ́Ч»**, к. *«Ялкын»*.

**ЫШНАЛЫ́** елгасы, Идел алдында, Гөбенә елгасының (Зөя елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 17,5 *км*. Бассейнының мәйданы 103,6 $км^2$. Идел буе калкулыгыннан ага. Елга башы Кайбыч р-ны Ульянково авылыннан 4 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Яшел Үзән р-ны Рус Әҗиле авылыннан 2 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 55 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Ы.ның 0,4 тән 1,5 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,2 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Коры вакытта суы тамагына кадәр барып җитмәскә дә мөмкин. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 96 *мм*,ташу вакытында су агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 $м^3/с$. Ел дәвамында суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

# Э

**ЭВАКУА́ЦИЯ ГО́СПИТАЛЬЛӘРЕ**, хәрби хезмәтләрне стационар дәвалау учреждениеләре. Даими (гарнизон, округ) һәм сугыш чорында ачылган (эвакуация, күчмә-кыр, яралыларны төркемләп аеру, махсуслаштырылган) госпитальләргә бүленәләр. Бөек Ватан сугышы башлану алдыннан Кызыл Армиядә яралыларны этаплап дәвалап, шуннан соң билгеләнгән тәртиптә эвакуацияләү принцибы буенча В.А.Оппель тарафыннан эшләнгән (1916) һәм Б.К.Леонардов тәкъдим иткән (1931) төзек дәвалау-эвакуацияләү системасы барлыкка килә. Җиһазландырылган армия, фронт һәм тыл госпитальләре базасы, квалификацияле белгечләр булган шартларда әлеге принципның максатка ярашлылыгы Хасан күле (1938) һәм Халхин-Гол елгасы (1939) буендагы бәрелешләр, Финляндия б-н сугыш (1939–40) тәҗрибәсендә раслана.

Бөек Ватан сугышы башында респ-када 186 табиб һәм 5,5 меңнән артык урта мед. персоналы исәпләнә; кыска гына вакыт эчендә ТАССРда 50 мең ятак-урынга исәпләнгән 59 Э.г. корыла һәм җиһазландырыла, аларда 334 меңләп яралы дәвалау курсы уза. Көнбатыштан көнчыгышка таба су юллары һәм тимер юллар кисешкән уңайлы геогр. урыны, икътисади үсеш дәрәҗәсе, яхшы җиһазландырылган клиникалар базасы, ГИДУВта, мед. һәм стомат. ин-тларында тупланган югары квалификацияле мед. кадрлары булу аркасында 1941 елның июлендә үк Казан иң зур хәрби-дәвалау үзәкләре исәбенә керә.

Э.г. булдыру өчен клиникалар, институтлар, мәктәпләр, мәдәният сарайлары, клублар, тулай тораклар, кунакханәләр, шифаханәләр һәм ял йортлары урнашкан 70 тән артык иң яхшы бина файдаланыла, алар тиз арада госпитальгә кирәк булганча җиһазландырыла. 1941 нең июлендә Э.г.ндә ятаклар саны – 5, 1942 нең февралендә 8 тапкыр арттырыла. Сугышның унынчы көнендә үк Э.г. беренче яралыларны кабул итә. Татарстанның иң яхшы 10 госпитале мед. персоналы б-н бергә фронт яны полосаларына күчерелә. ТАССРда Э.г.н формалаштыру 1943 нең сентябрендә төгәлләнә. Гомумхирургия һәм терапия госпитальләре б-н бергә, Казанда махсуслаштырылган казналык-йөз, нейрохирургия, офтальмология, оториноларингология госпитальләре һ.б. үз эшләрен башлап җибәрә.

Госпитальләр базасында Казан галимнәре һәм дәвалаучы табибләр фәнни-тикшеренү эшләре алып баралар. 1942 нең 1 июлендә хәрби мед. буенча 132 тикшеренү тәмамлана. Госпитальләрдә шәһәрнең әйдәүче белгечләре – профессорлар А.Ф.Агафонов, В.Е.Адамюк, М.П.Андреев, А.В.Вишневский, Б.А.Вольтер, И.В.Домрачев, В.И.Катеров, Р.А.Лурия, З.И.Малкин, Л.И.Омороков, Д.М.Раппопорт, И.И.Русецкий, Н.В.Соколов, Ә.Б.Терегулов, Л.И.Шулутко һ.б. эшли. 1941 нең 6 аенда – 2 меңләп, 1942 нең июлендә генә дә 1,5 меңләп операция ясала. 1942 нең апрель-маенда армиягә яралыларның 40–45%ы, ел ахырына 62,5–72% ы кабат кайта.

Госпитальнең профиленә карап системалы рәвештә барлык баскыч мед. хезмәткәрләрен аттестацияләү, аларның квалификациясен күтәрү һәм камилләштерү уздырыла. Сугышның беренче елында ГИДУВ респ-ка госпитальләре өчен 743 хирург әзерли. Әйдәүче хирурглар вазифаларына яшь табибләр Ш.Х.Байбикова, Я.Н.Ефремов, А.М.Калгатина, Л.С.Любимов, Н.П.Медведев һ.б. тәкъдим ителә. Сугыш чорында ел ярымда 2,6 меңнән артык табиб квалификация күтәрү курслары уза. Кыска вакытлы курслар һәмункөнлекләр аша казналык-йөз һәм оператив хирургия, хәрби хирургия, эпидемиология һ.б. белгечлекләр буенча 428 табиб әзерләнә. 1942 дә шәфкать туташлары мәктәпләрендә һәм курсларында 1232 белгеч (шәфкать туташлары, мед. техниклары, лаборантлар) әзерләп чыгарыла. Сугышның беренче елларында Кызыл Хач җәмгыяте тарафыннан госпитальләрдә эшләү өчен 569 санитар кыз җибәрелә, яшьләрне массачыл рәвештә санитарлык эшенә өйрәтү оештырыла. 1941 нең декабрендә үк 2,5 мең кеше укуны тәмамлый.

1941 дә Респ-ка физкультура һәм спорт ком-ты 100 дән артык дәвалау гимнастикасы инструкторы әзерли, 1942 ел башына Э.г.ндә Т.К.Шулейкина җитәкчелегендә 204 спортчы дәвалау гимнастикасы алып бара. Белгечләр әзерләү ГИДУВта туплана, дәресләрне Л.И.Шулутко, А.Плещицер, Н.Герасимова, А.Ионина, О.Войдинова һ.б. уздыра. Респ-каның спорт җәмгыятьләре тарафыннан дәвалау физкультурасы б-н шөгыльләнү өчен заллар, җиһазлар, инвентарь бүлеп бирелә. Авыр яралыларның 72% ында мөһим хәрәкәтләнү функцияләре торгызыла.

Халыкның яралы сугышчыларга хезмәт күрсәтүенең бер формасы шефлык итүдән гыйбарәт була. 1941 нең декабрендә Татарстандагы 59 Э.г.нә 445 пр-тие, колхоз, мәктәп, югары уку йортлары шефлык итә. Алар яңа дәвалау учреждениеләрен коруда һәм формалаштыруда, яралыларны яңа әзерләнгән ашамлыклар һәм индивидуаль бүләкләр б-н тәэмин итүдә ярдәм күрсәтәләр. 1942 нең ноябрь-декабрендә шефлар госпитальләргә 26 мең пот азык-төлек һәм 16,5 мең данә бүләк китерәләр; һәркөн шәһәрнең 600 дән артык пропагандисты һәм агитаторы яралылар алдында лекцияләр, докладлар б-н чыгышлар ясый, әңгәмәләр уздыра, концертлар күрсәтә. Яралыларга ярдәм итү ком-тлары госпитальләр каршындагы түгәрәкләр, курслар һәм остаханәләр системасы аша хезмәт күнекмәләренә өйрәтү б-н шөгыльләнәләр. Татарстан госпитальләрендә 6 меңнән артык фронтовик белгечлек ала. Бөек Ватан сугышы елларында сугышчыларга мед.-сан. хезмәте күрсәтүне оештыруга ш.у. гражданнар дәвалау-мед. учреждениеләре дә җәлеп ителә. Мед. хезмәткәрләре 90% тан артык авыруны сафка кайтаралар.

*Әд.:* К о н о п л е в А.Ю., С а л а х и е в а М.Ю., С а л а х и е в Р.Р. Историческая справка о функционировании эвакогоспиталей на территории Татарстана в годы Великой Отечественной войны // Я вечно помнить призываю: Каталог госпитальных воинских захоронений периода Великой Отечественной войны на территории Республики Татарстан. К., 2009; С а л а х и е в Р.Р., С а л а х и е в а М.Ю., А л е к с а н д р о в А.А. Здания эвакогоспиталей в Татарстане (1941–1945): Фотоальбом. К., 2015.

*Р.А.Худякова.*

**ЭВЕРСМА́Н** Эдуард А л е к с а н д р о в и ч (11.1.1874, Вестфалиядә Хаген ш. янында Верингхаузен а. – 14.4.1860, Казан), натуралист, табиб, сәяхәтче, фәлсәфә д-ры (1814), медицина д-ры (1816), Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1842). Германиядә белем ала. 1816 елда Россиягә күчә һәм Златоуст шәһәрендәге корал ф-касында табиб булып эшли (1818–20). Бохарага һәм Устюртка оештырылган беренче рус экспедицияләрендә катнаша, беренчеләрдән булып Россия империясенең күп кенә төбәкләрен: Казан губернасыннан Аралга кадәр араны, Каспий буе һәм Кавказ алдын тикшерә. 1828 дән Казан ун-тында: ботаника һәм зоол. каф. профессоры, 1837 дән зоол. кафедрасының беренче мөдире, каф. профессоры. Бер үк вакытта, 1833 тән, Казан җәмәгать тәрбиясе приказы хастаханәсе баш табибе; 1841–42 дә Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты табибе. Бер үк вакытта, Казан Зоол. музее б-н җитәкчелек итә, кошларның – 125, имезүчеләрнең 11 төре һ.б. б-н коллекцияләрне тулыландыра. Ул эшләгән вакытта зоол. коллекцияләре тупланмалары системалаштырыла. Сәяхәтләр вакытында бай зоогеогр. материал туплый, имезүчеләр, кошлар, бөҗәкләрнең яңа төрләрен ача, систематикага, биологиягә, төрле хайван төрләренең таралышына тулы тасвирлама бирә. Россиядә беренчеләрдән булып корткычлар б-н көрәштә биол. алымнар тәкъдим итә. Идел һәм Арал диңгезе арасындагы терр-яне Э. Оренбург крае дип атый. 3 томлы «Оренбург краеның табигыять тарихы» («Естественная история



Э.А.Эверсман.

Оренбургского края» (Оренбург-К., 1840–66) китабы авторы, бу хезмәттә ул имезүчеләрнең 100 төрен тасвирлый, кошларның 332 төрен һ.б.ны күрсәтә. Э. далаларның үзенчәлекле килеп чыгышы турындагы гипотезаның авторы дип исәпләнелә. Тәңкәканатлылар турындагы монографиясе өчен Демидов бүләге ала (1845). Берлиндагы Король табигыятьчеләр җәмгыяте, Афина, Прага табигыятьчеләр җәмгыятьләре, Рус геогр. җәмгыяте һ.б. әгъзасы. Казан ун-тының атказ. профессоры (1853). 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә. Казан ун-тының Зоол. музеена (2004), хайваннарның 14 төренә, үсемлекләрнең 1 ыругына һәм 2 төренә Э. исеме бирелә.

Х е з м.: Описание чешуекрылых насекомых, находящихся между Волгой и Уральским хребтом // Казан. вестн. 1831. Апр.-окт.; Речь о пользе наук естественных и в особенности зоологии // Обзор преподаваний в Императорском Казанском университете за 1839–1840 учебный год. К., 1839.

*Әд.:* Г а р а н и н В.И. Жизнь и деятельность Э.А.Эверсмана. К., 2002.

**ЭВРА́НОВА** Валентина Георгиевна (29.10.1916, Евпатория ш. — 12.5.2006, Казан), гельминтолог, вет. фән. д-ры (1964), проф. (1964), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1976). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1938), шунда ук эшли, паразитология каф. мөдире (1959–90). Тикшеренүләренең төп юнәлеше гельминтларның хайван организмына патоген тәэсирен өйрәнүгә карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Методы лабораторной диагностики главнейших гельминтозов сельскохозяйственных животных и промысловых животных и сравнительный анализ их эффективности // Уч. зап. Казан. вет.ин-та. 1960. Т. 72; Диагностика гельминтозов жвачных. К., 1981.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

**ЭЗМӘ́** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 11 *км* төньяктарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 316 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Төзелеш пр-тиесе. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Деревня по речке Сунер, Изма-Сунер исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Э.дә мәчет, мәктәп, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 806,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 87 ир-ат; 1859 да — 280, 1897 дә — 612, 1908 дә — 699, 1920 дә — 688, 1926 да — 749, 1938 дә — 714, 1949 да — 520, 1970 тә — 397, 1979 да — 362, 1989 да — 342, 2002 дә — 335 кеше.

**ЭЙДИ́НОВ** Григорий Львович (22.12.1946, Казан), график, нәкышьче, китаплар бизәүче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2003), РФнең атказ. рәссамы (2008). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1966), Чуаш пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын (1979) тәмамлый. 1968–74 елларда Казан сәүдә рекламасы комб-тында рәссам-проектлаучы, 1976–91 дә — Татарстан китап нәшрияты (1968 дән хезмәттәшлек итә), 1991–2002 дә — ТР Сәнгать фонды рәссамы. 2002 дән «Казан» ж-лы баш рәссамы. Бер үк вакытта «Заман» нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә (2003 тән), Казан сынлы сәнгать уч-щесендә (2007 дән), В.И. Суриков исем. Мәскәү акад. сынлы сәнгать ин-тының Казан ф-лында укыта (2009 дан). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1989). Э. китап бизәүдә һәм станлы графикада (рәсем, линогравюра, офорт, акварель, сепия, пастель һ.б.), плакат сәнгатендә уңышлы эшли. Россия һәм чит ил компанияләре өчен ясалган логотиплар, товар тамгалары, фирма стильләре авторы. Рәссамнар иҗат төркеме составында РФ Дәүләт гербын эшләүдә катнаша (1990). Китап һәм журнал графикасын үстерүгә зур өлеш кертә. Э. иллюстрацияләрне еш кына офорт, акварель, темпера, тушь, гуашь, акрил техникасында, станлы авторлык сериясе буларак иҗат итә: В.Гаршинның «Сәяхәтче бака» («Лягушка-путешественница», 1983), А.Милнның «Винни-Пух» (1987), Г.Маркесның «Ялгызлыкта йөз ел» («Сто лет одиночества», 1987), В.Гюгоның «Гаврош» (1988), М.Булгаковның «Эт йөрәге» («Собачье сердце», 1988) һәм «Мастер һәм Маргарита» («Мастер и Маргарита», 1989–2009), З.Мансурның «Елак куян» (1988), А.Алиш әкиятләре (1988), татар халык әкияте «Үги кыз» (1982–2009), «Фирүзә» (2010) китаплары, «Шәһәр әкиятләре» («Городские сказки», 2010) җыентыгы һ.б. Китап дизайнында Э. үз стилистикасын булдыра һәм ул «Казан» журналын, Л.Похвалинскаяның «Тылсымлы фарфор доньясы» («Волшебный мир фарфора», 2003), «Татарстанда Җир Хартиясе» («Хартия Земли в Татарстане»; 2005; 3 нче басмасы 2011), Г.Милашевскийның «Иске Казан. Фотопортрет» («Старая Казань. Фотопортрет», 2006) альбомнарын һ.б. бизәүдә концептуаль чагылыш таба.

Э. ның станлы графикасы киеренке лирик хиссият, шартлы-символик композициядән алып хикәяләү характерындагы гомумиләштерүгә кадәр киң сәнгати диапозон б-н аерыла: «Чабаксар шәһәре күренешләре» (1978), «Цирк» (1985), «Г.Тукай буенча» (1986), «Казан альбомы» (1991–2011), «Татар әкияте доньясы» (1997), «Булгаковча төшләр» (2000), «Төркия буйлап» (2001), «Зөя шәһәрчеге» (2010), «Яранск» (2011), «Гороховец» (2012). 2000 еллардан башлап Э. пейзаж, сюжетлы картина жанрында станлы нәкышь б-н актив шөгыльләнә. Татарстанның борынгы шәһәрләре Казан, Зөя, Алабуга, ш.у. Касыйм, Яранск, Гороховец һ.б. шәһәр күренешләрен натурадан сурәтләгән ландшафтлы һәм архитектур пейзажлар авторы. Э.ның жанрлы әсәрләре: «Күчеш», «Трояндагы этюдларда» (икесе дә — 2001), «Язгы көз» (автопортрет), «Мишада кунакта» (икесе дә — 2002), «Уйдырмалар» сериясе (2008), «Казанкада регата», «Алып белән очрашу» (икесе дә — 2012. «Көзге натюрморт» (2000), «Карт барабанчы» (2000), «Төрек сувенирлары»







Г.Л.Э й д и н о в. 1. «Эт йөрәге». «Булгаковча төшләр» сериясеннән. Кәгазь. Темпера. 2000; 2. «Язгы көз». ДВП. Акрил. 2002. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. «Алып белән очрашу». Киндер. Акрил. 2012.



Э.И. Эйхвальд.

(2001), «Ретро», «Онытылганнар» (икесе дә — 2002) һ.б.

1973 тән башлап төбәкара — «Зур Идел» күргәзмәсендә (1980–2011); бөтенроссия — «Совет Россиясе» (1980–86), «Россия» (1998–2009), «Рәссам һәм вакыт» (1987) күргәзмәләрендә (Мәскәү; бөтенсоюз — Бөтенсоюз сәнгать (1990), «Татарстан сәнгате» (2005), Г.Тукайның 120 еллык, М. Җәлилнең 100 еллык юбилейларына багышланган (икесе дә — 2006) күргәзмәләрдә, халыкара сынлы сәнгать атналыкларында (2010) (барысы да — Мәскәү); Төркиядә уздырылган Тукай көннәрендә (2006, Истанбул); «Яңа графика» (2007), «Г.Тукай юбилеена 125 иллюстрация» (2011), «Ак һәм кара» (2012) һ.б. күргәзмәләрдә (Казан) катнаша. Шәхси күргәзмәләре 2001, 2002 (В.Анютин б-н бергә), 2011, 2012, 2013, 2017 дә Казанда; 2006 да (Р.Газиев б-н бергә) Истанбулда, Казанда, 2007 дә Алабугада, 2011 дә Яранскида, Кировта, Киров өлкәсе Кирово-Чепецк шәһәрендә уздырыла. Б.Урманче исем. (2001), халыкара «Елның иң яхшы китап тышлыгы» конкурсының «Алтын циклоп» (2004), ТР Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм» (2006) бүләкләренә лаек була. 6 тапкыр Бөтенроссия «Китап сәнгате» китап графикасы конкурсы лауреаты (1980–89). Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Г.Тукайның Казандагы әдәби музеенда, Яңа Кырлай авылындагы Г.Тукай әдәби-мемориаль музей комплексында, Алабуга дәүләт архит-ра-сәнгать музей-саклаулыгында, Вятка дәүләт А. һәм В.Васнецовлар исем. сынлы сәнгать музеенда (Киров), Рязань өлкәсе Касыйм шәһәрендәге Тарих музеенда, Төркиядәге Чанаккала шәһәре музеенда саклана. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Хисамова Д. Своё слово в искусстве // Казань. 2006. № 10/11; Григорий Эйдинов. Живопись. Графика. Книга: Каталог. К., 2012.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**Э́ЙХВАЛЬД** Эдуард Иванович (Карл Эдуард) (4.7.1795, Латвиянең Митава ш., хәзер Елгава ш. — 4.11.1876, Петербург), табигыять галиме, медицина д-ры (1819), Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1826). Берлин ун-тын тәмамлый (1817). 1819–21 елларда Дерпт ун-ты профессоры. 1823–29 да Казан ун-тында: зоол. каф. профессоры, бер үк вакытта ун-тның Ботаника бакчасы җитәкчесе (1824–25). Чагыштырма анатомия кабинетын нигезли, табигыять тарихы кабинетын Арал-Каспий өлкәләренә оештырылган экспедицияләр вакытында җыелган күп кенә ботаник, зоол. һәм палеонтологик коллекцияләр б-н тулыландыра. 1829 дан Вильно ун-тында (Литва, хәзер Вильнюс ш.). 1838 дән С.-Петербургта: Мед.-хирургия академиясендә (1851 гә кадәр); бер үк вакытта, 1839–55 тә, Петербург тау ин-тында палеонтология һәм Николаев инженерлык академиясендә минерал. буенча лекцияләр курсы укый. Хезмәтләре палеонтологиягә, геологиягә, минералогиягә, фауна һәм флорага карый. Э. тарафыннан Каспий-Кавказ фаунасының (башлыча, моллюсклар, балыклар һәм сөйрәлүчеләр), үсемлекләрнең яңа төрләре тасвирлана, үзе булган районнарның географиясе буенча мәгълүматлар китерелә, «хайваннар патшалыгы»ның яңа системасы тәкъдим ителә. Казан ун-тының атказ. профессоры, шәрәфле әгъзасы (1873).

Хезм.: Полный курс геологических наук преимущественно в отношении к России: В 2 ч. СПб., 1844–46; Геогнозия преимущественно в отношении к России. СПб., 1846; Палеонтология России: В 2 ч. СПб., 1854–61.

*Әд.:* БСЭ. 3 изд. М., 1978. Т. 29.

**ЭЙХЕНВА́ЛЬД** Антон Александрович (13.5.1875, Мәскәү — 1952, Ленинград), композитор, дирижёр, музыка этнографы, педагог, музыка җәмәгать эшлеклесе, рәссам, БАССРның халык артисты (1945). 1892 елда Мәскәү сынлы сәнгать, скульптура һәм архит-ра уч-щесен (В.Поленов һәм В.Маковскийда сынлы сәнгать классы) тәмамлый; Н.Кленовскийда гармония, С.Танеевта контрапункт, Н.Римский-Корсаковта инструментовка дәресләре ала. 1893–1917 дә Казан (1893), Саратов, Түбән Новгород, Тифлис, Баку һ.б. шәһәрләрдә антрепренёр, дирижёр, хормейстер, опера труппалары рәссамы. 1917 дән соң төрле шәһәрләрдә иҗат эшен дәвам итә. Казанда Э.ның татар һәм башкорт халык көйләренә нигезләнгән әсәрләреннән торган симф. концертлары зур яңгыраш ала (1923). 1924–28 дә эмиграциядә — Франция, Бельгия, Швейцариядә опера һәм симф. оркестрлар б-н дирижёрлык итә. 1928 дән СССРның күп кенә шәһәрләрендә (Ашхабад, Уфа, Куйбышев һ.б.) дирижёр һәм педагог булып эшли. 1937 дә репрессияләнә (1938 дә азат ителә, 2003 тә аклана). Урта Азия, Идел буе халыкларының 4 меңнән артык традицион җырларын җыя. Татар һәм башкорт сюжетларына оперлар авторы: «Дала» («Степь», 1928; 2 нче редакция 1930 да; 1931 дә Урта Идел төбәк опера сәхнәсендә куела, Самара ш.), «Мәргән» (1937), «Ашказар» (1940; 1940 та икесе дә Башкорт опера һәм балет театрында куела, Уфа), «Кояшлы таш» («Солнечный камень», Г.Тукай әкияте буенча, 1946; куелмаган). Әсәрләре: 5 муз. комедия, ш.и. «Тәмәке капитаны» (1942, Куйбышев опера һәм балет театры); «Жар-птица» (Париж «Альгамбра» театрында «Иван-царевич» исеме б-н куела, 1925) балеты; Төрекмән ССРның 10 еллыгына (1934), БАССРның 25 еллыгына (1944) багышланган кантаталар; симфонияләр, камера-инструменталь әсәрләр, драма спектакльләренә музыка, якынча 50 романс һәм җыр һ.б.

*Әд.:* Славный юбилей (к 75-летию А.А.Эйхенвальда) // Советская музыка. 1950. № 7.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ЭКИПАЖЛА́Р ЯСА́У КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́**, транспорт чараларын (чана, арба, тарантас, карета, кибитка һ.б.) вак һөнәрчелек алымы б-н җитештерү. Казан губернасында 18 йөз уртасында барлыкка килә. Казан Себер трактындагы үзәк станцияләрнең берсе, Урта Азия, Себер һәм Ерак Көнчыгышка бару юлындагы транзит сәүдә һәм йөкләр ташу үзәге була, бу Э.я.к. продукциясенә ихтыяҗны арттыра. 19 йөз башыннан Казан губернасы осталары тарафыннан җитештерелгән кареталар, кибиткалар, тарантаслар һәм арбалы транспортның башка төрләре бөтен Россия буенча популярлык казана. Э.я.к.нең экипажлы (арбалар, чаналар һ..б.ясау) һәм тәгәрмәчле (экипаж тәгәрмәчләре, чана табаннары һәм дугалары эшләү) төрләре була.



Карета.

Экипажлар җитештерү традицион эш кораллары җыелмасын үз эченә алган столярлык кәсепчелегенең бер төрен тәшкил итә. Тәгәрмәчләр һәм кыршаулар әзерләү берничә стадиядән тора һәм аеруча катлаулы була. Вак һөнәрченең төп җиһазлары һәм эш кораллары — казанлы пешекләү бүлмәсе, верстак, божралар, куеп бөгү өчен бүкән яисә өстәл, тигезләгечләр, ш.у. балта, пычкы, бораү, өтерге, чүкеч, ышкылар. Вак һөнәрчеләр экипажларны заказ алып яисә җирле базар ихтыяҗын күздә тотып эшлиләр. Казан губернасының Казан һәм Минзәлә өязләре (900 гә якын хуҗалык исәпләнә) осталары шәһәр экипажлары — тарантаслар, кареталар, кибиткалар һәм җиңел арбалар эшләүдә махсуслаша. Заказ бирүченең җитешлегенә, социаль хәленә карап, тарантаслар төрле рәвештә: үрелгән гади арбадан башлап, күн б-н тышлап, ян-яклары металл канатлар б-н эшләнгән һәм рессорларга утыртылган кузовларга кадәр ясала. Озак сәяхәтләр өчен татар сәүдәгәрләре күбесенчә ябулы тарантаслар эшләтәләр. Арбалар, чаналар һәм аларның аерым өлешләрен җитештерү Сембер губернасының Сембер өязендә, Уфа губернасының Эстәрлетамак һәм Минзәлә өязләрендә, Вятка губернасының Глазов өязендә, Казан губернасының Лаеш, Спас һәм Чистай өязләрендә яшәгән татарлар арасында таралган була. Мәс., 19 йөз ахырында Вятка губернасы Алабуга өязендәге татар авыллары — Кырынды һәм Тордалыда 40 тан артык вак һөнәрче чаналар һәм тәгәрмәчләр җитештерү б-н шөгыльләнә. Тәгәрмәч ясаучы осталар арасында махсуслашу күзәтелә: бераүләр тугымнарын, икенчеләре — кигиләрен һ.б. әзерли.

Пенза губернасы Краснослободский өязе Тенеш авылында яшәүчеләрнең күбесе дугалар бөгә. 19 йөз уртасыннан дугалар ясау кәсепчелеге Лаеш өязенең Түбән һәм Югары Тегермәнлек, Яныш, Казаклар, Балтач авылларында үсеш ала. Түбән һәм Югары Тегермәнлек авылларыннан 160 хуҗалыкта гына да ел саен 120 меңләп дуга җитештерелә. Балтач авылында кәсепчелек б-н өлкән яшьтәгеләрнең һәммәсе шөгыльләнә. Иң киң таралган җәйге арба агач яисә тимер күчәрле арба була. Һәрбер атлы хуҗалыкта агач күчәрле арба файдаланыла. Тышкы күренеше б-н ул төбәктә киң таралган рус арбасына якын, әмма кузовның алгы һәм арткы өлешләре биегрәк итеп эшләнә. Агач, көлтә ташу өчен махсус арбалар; сәүдәгәрләр заказы буенча — тимер күчәрле арбалар, үзенә күрә күчмә кибет җитештерелә. Сәүдә вакытында кузовның аерым өяларына колгалар куела, аларга калын киндердән түбә тарттырыла; яннан үлчәүне ныгыту өчен элмәк җайлана. Кышкы экипажлардан утын чаналары, такта б-н тышланган чаналар, канатлы үрәчәле чаналар киң тарала. Моннан тыш, аркалы яки кәнәфиле, чыпта яисә тукыма б-н тышланган чаналар да ясала. Сәүдәгәрләр өчен гадәти көймәле рус чаналары тибындагы ябулы чаналар эшлиләр, алар тимер юл б-н йөкләр күчерү барлыкка килгәнче файдаланыла. Э.я.к. барыннан да элек җирле кулланучыларны күздә тота. Көймәле арбалар ш.у. Әстерханга, Оренбургка, Урал шәһәрләренә, Түбән Новгород һәм Эрбет ярминкәләренә чыгарыла. 20 йөз башында пароходчылык, тимер юл һәм автомобиль транспорты үсешенә бәйле рәвештә Э.я.к. бетүгә йөз тота. Индивидуаль заказ буенча экипажлар (чаналар, арбалар, сирәгрәк — тарантаслар) осталар тарафыннан 1970 елларга кадәр җитештерелә.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала. К., 1995; Суслова С.В., Мухаметова Р.Г. Народный костюм Поволжья и Урала. К., 2000.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ЭКЛЕ́КТИКА** (грек. eklektikós — сайланган, аерып алынган), төп структураларын аңлы рәвештә сайлап алуга, төрле архитектур стильләрнең бер корылмадагы элементларын ирекле рәвештә кушуга нигезләнгән сәнгать юнәлеше. Э. Европа һәм Россия архит-расында 1830–90 елларда өстенлек итә. Россия провинциясендә Э. 20 йөз башына кадәр модерн б-н янәшә үсеш ала. Европа архит-ра гыйлемендә Э. романтизм (19 йөзнең 2 нче чиреге) һәм тарих (19 йөзнең 2 нче яртысы) б-н бәйләп карала.

Эклектиканың архит-рада барлыкка килүенә антик формаларның һәм алар б-н бәйле архитектур стильләрнең (ренессанс, барокко, классицизм) өстенлек итүенә каршы протест буларак барлыкка килгән антиакадемизм булышлык итә. Э.да архитектур формаларның мәгънәви функциясе тулысынча бина стилен формалаштыручы декорга күчә, бу вакытта план һәм күләм формалары идея-эчтәлек мәгънәсен югалталар.

Э. Россиядә ике этапта — 1830–60 елларда һәм 1870–90 елларда үсеш ала һәм берничә юнәлешкә таркала. Беренче этапның башлануы, кискен регламентлаштырылган стиль буларак, классицизмга каршы кую б-н бәйле. 1830–40 елларда Россиядә арх. К.А.Тон нигез салган рәсми рус-византия стиле өстенлек итә. Аның проектлары буенча, Мәскәүдә Коткаручы Христос соборы, Зур Кремль сарае, Николай (Ленинград) вокзалы һәм Петербургта Мәскәү вокзалы, Казанда *Губернатор сарае* төзелә. Әлеге биналарның фасадларын бизәгәндә ул классик, ренессанс һәм борынгы рус архит-расы элементларын берләштерә. Моның б-н бергә, Э.ның беренче этабында архитекторлар урта гасырлар архит-расы образларына мөрәҗәгать итеп, готика, роман һ.б. архитектур стильләрдәге үрнәкләр һәм элементлар кулланылган романтизм юнәлеше









**Эклектика.** 1. Рус-Византия юнәлеше: Кремльдә Губернатор сарае. Казан. 1842, архитекторы К.А.Тон; 2. Роман-готика юнәлеше: Санкт-Катарина кирхасы. Казан, 1865, архитекторы Л.К.Хрщонович; 3. Классик юнәлеш: Александровлар пассажы. Казан. 1883–86. Архитекторлары В.В.Суслов, Н.И.Позднеев, Г.Б.Руш; 4. Романтик юнәлеш: Ушкова йорты. Казан. 1904–07. Архитекторы К.Л.Мюфке; 5. Милли-романтик юнәлеш: Печән базары мәчете. Казан. 1845–49. Архитекторы А.К.Ломан; 6. Рациональ юнәлеш: Сәнәгать училищесе. Казан. 1896. Архитекторы К.С.Олешкевич; 7. Милли-романтик юнәлештә «Кирпеч стиле»: Богоявление чиркәвенең чаң манарасы. Казан. 1895–97. Архитекторы М.Д.Михайлов.

барлыкка китерәләр. Готика архит-расы формалары рух хөрлеге, тарихка мөрәҗәгать итү һәм мәдәниятнең милли кабатланмаслыгы б-н ассоциацияләшә. Э.ның роман-готика стилендә *Казандагы Санкт-Катарина кирхасы* төзелә, Казан ун-ты китапханәсе интерьеры бизәлә (1830 еллар, арх. М.П.Коринфский). 1850 елларның 2 нче яртысыннан Э.ның готика юнәлеше орнаментта крәстиян сюжетлары (бизәкләр чигү, уеп бизәк төшерү, чыпта үреме һ.б.) һәм төрле ачык төсләр тулылыгы б-н сыйфатлана. Казан губернасында бу юнәлеш агач торак архит-расында ачыла.

Классицизм кануннарын кире кагу Э.ның классик юнәлешләрен тәшкил иткән барокко, ренессанс, грек-рим, Людовик XIV һ.б. кебек барлык акад. стильләрдән тулысанча баш тартуны чагылдырмый. 19 йөз дәвамында Э.ның классик стилендә музейлар, китапханәләр, уку йорты биналары, мунчалар, банклар, табыш йортлары һәм утар йортлары калкып чыга. 19 йөзнең 2 нче яртысында Казанда Э.ның әлеге юнәлешендә 20 дән артык архитектор: П.Е.*Аникин*, А.К.*Ломан*, Ф.Н.*Малиновский*, П.Т.*Жуковский*, И.П.*Бессонов*, А.И.*Песке*, П.И.*Романов*, П.В.*Тихомиров*, В.Н.*Бечко-Друзин*, Л.К.*Хрщонович* һ.б. эшли. Казанда аларның иҗаты *Алафузов театры*, *Дворяннар җыены*, Реаль уч-ще, Казан губернасы шәһәрләрендә — *Чистайдагы беренче ир балалар гимназиясе*, *Чистай шәһәренең беренче җамигъ мәчете* биналарыннан, күпсанлы утар йортлары һәм табыш йортларыннан гыйбарәт була.

1870 елларда Э.ның мөстәкыйль агымнары — милли-романтик (милли стиль) һәм рационалистик стильләр барлыкка килә. Казан губернасында рус һәм романтик юнәлешләрдәге милли колорит рус һәм татар буржуазиясенең яшәү мохитенә милли мәдәният рухы һәм Европа архит-расының иң яхшы казанышларын кертергә омтылыш б-н бәйле. Казанда *Печән базары мәчете*, Солтан мәчете, *Подуруева, Ушкова* йортлары һ.б.ш. барлыкка килә. Иске татар бистәсендә *Апанаевлар, Шамил* йорты һ.б. аерылып тора. Казанда Э.ның милли-романтик юнәлештәге вәкилләре: архитекторлар Г.Б.Руш, К.Л.Мюфке, Ф.Р.Амлонг һ.б. *Әҗем мәчете* һәм *Борнай мәчете*, *«Шакир солдат» йорты* һ.б. шәркый-мөселман өлгеләре кушылган архит-ра ядкәрләренең аерым биналар төркемен карыйлар.

Рационализм утка чыдам тышлык кирпеченнән рациональ файдаланылуга корылган «кирпеч стиле»нең символына әверелә: *Казан Университетының яңа клиникалары* шул стильдә төзелә. Шушы ук стильгә Э.ның ачык колонналар, түбә ябу конструкцияләренең гадилеге, зур тәрәзә уемнары, штукатурадан баш тарту һ.б.да чагылыш тапкан сәнәгать юнәлеше кушылып китә. Уку биналары (сәнәгать уч-щесе) һәм сәнәгать архит-расы Э.ның рационалистик стилендә үсеш ала: *Крестовниковлар заводы биналары комплексы, Александров И.В. варисларының сыра һәм сосла кайнату заводы комплексы* һ.б.

Бер үк бина бизәлешендә Э.ның берничә юнәлеше һәм стиль агымнары аралашып килергә мөмкин: *Богоявление чиркәвенең* чаң манарасы, Зөя шәһәренең Иоанн-Предтеча монастырендагы (хәзер Успение монастыреның кунак йорты) «Барлык хәсрәтлеләр юанычы» Мәрьям Ана иконасы соборы. Казандагы *Тимер юл вокзалы* рус һәм «кирпеч» стильләре аралашкан милли-романтик юнәлештә бизәлгән; *Александровлар пассажы* һәм *Чернояров пассажы* Э.ның классик һәм милли-романтик стильләрендә чишелеш тапкан.

*Әд.:* К и р и ч е н к о Е.И. Русская архитектура 1830–1910-х годов. М., 1982; П и л я в с к и й В.И., Т и ц А.А., У ш а к о в Ю.С. История русской архитектуры. Л., 1984.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ЭКОЛО́ГИЯ** (грек. óikos — өй, торак, урын һәм ...*логия*), тере организмнарның, алар бергәлегенең үзара һәм әйләнә-тирә б-н бәйләнешен өйрәнүче фән. Организм дәрәҗәсеннән югары торган системаларны: популяцияләр, биоценозлар, *биогеоценозлар* (экосистемалар), *биосфераның* төп оешу һәм эшчәнлек принципларын тикшерүче гомуми Э.гә, һәм конкрет таксономик төркемнәрне өйрәнүче аерым кулланылышлы Э.гә бүленә. Тикшерү объектларына бәйле рәвештә үсемлекләр Э.се, хайваннар Э.се, бактерияләр Э.се, гөмбәләр Э.се, ш.у. XX йөз урталарында формалашкан, кешелек җәмгыятенең табигать б-н үзара тәэсир итешүе мәсьәләләрен тикшерүче кеше Э.сенә яки социаль Э.гә аералар. Ш.у. тере организмнарны тикшерү дәрәҗәсенә бәйле рәвештә Э.не аутоэкология (аерым төрләрнең әйләнә-тирә б-н үзара тәэсир итешүен тикшерә) һәм синэкологиягә (биогеоценозларны һәм бергәлекләрне тикшерә) бүлү кулланыла.

Э. йогынтысында күп кенә биол. фәннәрдә тере организмнарның теге яки бу якларын өйрәнүче юнәлешләр формалаша: экологик физиология, экологик морфология, экологик генетика һ.б.

«Э.» термины 1866 елда немец биологы Э.Геккель тарафыннан тәкъдим ителә, ул Э.не «организмнарның әйләнә-тирә мохиткә тәэсирен өйрәнүче гомуми фән» дип атый. Мөстәкыйль фән буларак Э. 20 йөз башында формалаша, 20 йөзнең 1 нче яртысында төрләрнең әйләнә-тирә мохит шартларына яраклашуы — *адаптация*се Э.нең төп нигезләреннән берсе буларак танылa. В.И.Вернадский биосфера турында фундаменталь тәгълимат тудыра (1926). Инглиз ботанигы А.Тенсли үзара һәм терек булмаган әйләнә-тирә б-н бәйле организмнар комплексын күздә тоткан экосистема төшенчәсен кертә (1935). СССР галиме В.Н.Сукачёв тарафыннан биогеоценоз төшенчәсе тәкъдим ителә (1940). *Әйләнә-тирә мохитнең пычрануы* көчәя бару һәм кешенең табигатькә йогынтысы арту сәбәпле, 20 йөзнең 2 нче яртысында Э.нең гамәли әһәмияте үсә, биол. фәне кысасыннан чыгып, ул геогр., геол., химия, физика, социол. һ.б.ны үз эченә алган, ш.у. *табигатьне саклауны* өйрәнүче фәннәр дә кушылган комплекслы фәнгә әверелә.

Татарстанда беренче экологик мәгълүматлар 18 йөз ахырында, эчәргә яраклы су алу өчен чишмә, бәке, Кабан күленнән файдалану, Казанда суүткәргеч төзелү, Болак ермагын чистарту уңае б-н тарала. 1805 тә Казан ун-ты ачылу Э.нең фән буларак формалашуына башлангыч бирә. Хайваннарның индивидуаль үсешен чагыштырма өйрәнү өлкәсендә эмбриологик хезмәтләр Э. үсешендә зур роль уйный, аларда Ч.Дарвин тәгълиматының дөреслеге исбатлана (А.О.Ковалевский, 1860 еллар). 19 йөз ахыры — 20 йөз башында үсемлекләр бергәлегенең (фитоценозларның) оешу закончалыклары, үсемлек капламының төрле сәбәпләр, ш.и. кеше эшчәнлеге йогынтысында үзгәреш кичерүе (С.Н.Коржинский, П.Н.Крылов) өйрәнелә. Б.А.Келлер тарафыннан экологик рәтләр (тереклек шартларының алмашынуы сәбәпле үсемлекләр ассоциациясенең үзгәрүенә нигезләнә) һәм үсемлекләр капламын морфологик-экологик өйрәнү (төрле җирдә үсүче беришле үсемлек формаларын өйрәнү) алымнары тәкъдим ителә. А.Я.Гордягин ботаник-геогр. һәм үсемлекләрнең туфрак һәм әйләнә-тирә, үсемлекләр капламының туфрак һәм геол. төзелеше б-н бәйләнешен билгеләү өчен фитоценологик тикшеренүләр үткәрә. 1940 елларда Т.Т.Работнов ботаника кафедрасында популяцион-ботаник тикшеренүләр (үсемлекләрнең популяцион Э.се) үткәрә башлый, соңыннан кафедра бу юнәлеш буенча илдә әйдәп баручы үзәкләрнең берсенә әверелә. Н.А.Ливанов тарафыннан хайваннар морфологиясен өйрәнүдә экологик-функциональ юнәлешкә нигез салына. А.А.Першаков Казан эколог-тетраподологлар мәктәбен (җир өсте умырткалы хайваннары буенча белгечләр) нигезли. 1950–80 елларда Казан эпидемиология һәм микробиол. фәнни-тикшеренү ин-тында В.А.Бойко җир өсте экосистемаларының структур-функциональ оешу мәсьәләләрен һәм аларның антропоген трансформациясен тикшерә, ландшафтларның антропоген трансформациясе тәэсирендә авыруларның табигый чыганаклы (талпан энцефалиты һәм бөер авыруы синдромлы геморрагик бизгәк) паразитар системалары оешуның үзгәрү закончалыкларын ачыклый. Татарстанда XX йөзнең 2 нче яртысыннан респ-када әйләнә-тирә мохитне саклау, экологик куркынычсызлык өлкәләрендә экологик халәтне яхшыртуга, төбәк биоценозларын саклауда ярдәм күрсәтү, табигатьтән файдалануны нормальләштерү һәм тере организмнарның яшәү шартларын яхшыртуга юнәлтелгән тикшеренүләргә елдан-ел зур игътибар бирелә башлый.

1969 да В.А.Попов җитәкчелегендә Казан ун-тының биол.-туфрак ф-тында СССРда беренче табигатьне саклау һәм биоценология каф. оештырыла (1990 да исеме гамәли Э. кафедрасына үзгәртелә). Каф. мөдирләре: В.А.Попов (1969–80), В.И.Гаранин (1980–86), Ю.С.Котов (1986–94), В.З.Латыйпова (1994–2015). Каф. хезмәткәрләре арасында геоботаник В.С.Порфирьев, герпетолог В.И.Гаранин бар; алар Идел-Кама табигый саклаулыгын оештыруда, Татарстанда аеруча саклануы терр-яләр системасын булдыруда катнашалар. 1989 да Э.ф-ты оештырыла, аның составына табигатьне саклау һәм биогеоценология каф. керә; 1990 да экологик системаларны модельләштерү каф. булдырыла (мөдире Ю.В.Голунков, 1994 тән — Э.В.Ск-

ворцов), ландшафт Э.се каф. (мөдире Н.П.Торсуев, 1999–2008 дә — О.П.Ермолаев, 2008 дән — В.В.Сироткин), 2003 тә гомуми Э. каф. ачыла (мөдире Т.В.Рогова).

Авыр металлар һәм пестицидларның биол. объектларда туплануы сәбәпле экологик-токсикологик фәнни юнәлешләр формалаша. 1993 тә ТР ФАнең Табигать системалары экологиясе ин-ты булдырыла (2009 да Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары ин-тына үзгәртелә), ул Казан ун-ты б-н берлектә су объектларын (Куйбышев, Түбән Кама сусаклагычлары, Зөя елгасы, Кабан күлләре һ.б.) өйрәнү буенча киң масштаблы гидрохимик һәм гидробиол. тикшеренүләр үткәрә. Респ-ка терр-ясендә эталон, сирәк, юкка чыга баручы туфракларны саклау һәм яңадан булдыруның экологик, фәнни-оештыру, хокукый нигезләрен эшләү максатыннан ТР туфракларының Кызыл китабын төзү буенча эшләр алып барыла.

1990 елларда әйләнә-тирә мохиткә бик аз күләмдә тәэсир ясаучы экологик технологияләрне булдыру һәм гамәлгә кертү б-н шөгыльләнүче инженерлык яки сәнәгать Э.се киң үсеш ала. Казан технол. ун-тында сәнәгать, а.х. җитештерүе калдыкларын, биол. актив өстәмәләр һ.б.ны куллану юлы б-н нефть химиясе, машина төзелеше, җиңел, азык-төлек сәнәгате пр-тиеләрендә агынты суларны чистарту технологияләре; Казан техник ун-тында — атмосферага чыгарылучы зарарлы матдәләрне чистарту технологияләре; Казан энергетика ун-тында — техник су б-н тәэмин итү системаларын тоз утырмаларыннан һәм биокапланулардан нанобиоцидлар ярдәмендә чистарту технологияләре һ.б. эшләнә.

ТР галимнәренең коллектив (күмәк) хезмәт нәтиҗәсе — «Татарстан Республикасының Кызыл китабы: Хайваннар, үсемлекләр, гөмбәләр» («Красная книга Республики Татарстан: Животные, растения, грибы», 1995, 2006, 2016). 1993 тән ел саен «Татарстан Республикасында табигый ресурсларының торышы һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча дәүләт доклады» («Государственный доклад о состоянии природных ресурсов и об охране окружающей среды Республики Татарстан») басылып чыга. Э. өлкәсендә фундаменталь һәм гамәли фәнни-тикшеренү хезмәтләрне кординацияләүне ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы б-н берлектә ТР ФА президиумы каршындагы Э. проблемалары буенча Фәнни совет башкара.

*Әд.:* О д у м Ю. Основы экологии. М., 1975; С н а к и н В.В. Экология и охрана природы: Словарь-справ. М., 2000; Актуальные экологические проблемы Республики Татарстан: Материалы 4-й Респ. науч. конф. К., 2000; На защите природы: К 15-летию образования Мин-ва экологии и природных ресурсов Республики Татарстан. К., 2008.

*И.Г.Кадошникова, Э.В.Гоголь.*

**ЭКОЛО́ГИЯ МОНИТО́РИНГЫ** (ингл. monitoring, лат. monitor — кисәтүче, искә төшерүче), дәвамлы рәвештә алып барылган даими күзәтүләр, антропоген йогынтылар тәэсирендә әйләнә-тирә мохит торышындагы үзгәрешләрне бәяләү һәм фаразлау системасы. Э.м.ның төп функцияләре: атм. һавасы, су, туфрак һәм ландшафтның башка компонентлары торышын контрольдә тоту; пычрануның төп чыганакларын билгеләү; ландшафтның төп компонентлары сыйфаты торышын фаразлау һ.б. Мәгълүматларны гомумиләштерү масштаблары буенча глобаль, милли, төбәк һәм локаль; эш алымнары буенча — биол. (биоиндикаторлар ярдәмендә), дистанцион (авиация, космик); күзәтү объектлары буенча кеше яшәгән тирәлек мониторингы (һава, су, туфрак), биол. мониторинг (флора һәм фауна) һ.б. Э.м.ларына аерып карала. Ш.у. Э.м.н шартлыча әйләнә-тирәлеккә тәэсир итү мониторингы һәм әйләнә-тирә торышының үзгәрешләре мониторингына аералар.

Гомуммилли һәм төбәк дәрәҗәсендәге Э.м.н оештыру тиешле башкарма органнарга йөкләнә, закон актлары һәм карарлар нигезендә алып барыла. Татарстанда Э.м. б-н төрле министрлыклар һәм ведомстволар, аерым алганда, ТР Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгы (җирләрнең торышы мониторингы), ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм ТР Дәүләт сан.-эпид. күзәтчелеге үзәге (халык сәламәтлегенең торышы), ТР Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе (атм. һавасы, җир өсте сулары, атм. явым-төшемнәре, туфрак мониторингы, радиация мониторингы), Казан ун-ты, ТР ФАнең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары ин-ты, Татарстан урман-тәҗрибә станциясе, Идел-Кама табигый саклаулыгы, Түбән Кама милли паркы (хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм ТРның аеруча саклаулы табигать терр-яләре мониторингы); Татарстан геол. разведка идарәсенең «Гидромониторинг» терр. фәнни-җитештерү үзәге (җир асты сулары мониторингы), «Геоцентр» фәнни-җитештерү берләшмәсе (Татарстанның барлык геол. мохите мониторингы — җир асты сулары, экзоген һәм эндоген геол. күренешләр), «Геомониторинг» терр. фәнни-җитештерү үзәге (иминлеге һәм нәтиҗәле кулланылышы максатларында геол. мохит торышын өзлексез тикшерү) һ.б. шөгыльләнә. Э.м. буенча оештыру, бердәм система булдыру һәм аны үстерү б-н бәйле координацияләү эшләре ТР Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан алып барыла.

*Әд.:* И з р а и л ь Ю.А. Экология и контроль состояния природной среды. Л., 1984; Ш е с т а к о в В.М. Мониторинг подземных вод — принципы, методы, проблемы. М., 1993; К о р о л ё в В.А. Мониторинг геологической среды. М., 1995; Г а т и я т у л л и н Н.С., Б у б н о в Ю.П., М е д в е д е в А.М. Мониторинг подземных вод — базовая основа обеспечения питьевого водоснабжения населения Республики Татарстан. К., 1996.

*С.И.Кадошников.*

**ЭКОЛО́ГИЯ ҺӘМ ҖИР АСТЫ́ БАЙЛЫКЛАРЫННА́Н ФАЙДАЛАНУ́ ПРОБЛЕ́МАЛАРЫ ИНСТИТУТЫ́**, ТР ФАнең структур бүлекчәсе. 2008 елда оештырыла. Институт составында 11 лаб., аларда 80 гә якын белгеч (биологлар, экологлар, географлар, геохимиклар, геологлар), ш.и. 9 фән докторы һәм 31 фән кандидаты эшли. Төп фәнни юнәлешләре — җир өсте һәм су экосистемаларының структур-функциональ төзелеше; агымның формалашу закончалыкларын, су ресурсларының торышын һәм кулланылышын өйрәнү; экологик мониторингның, экологик-аналитик күзәтчелек һәм нормалар булдыруның, су, һава, җир һәм биол. ресурсларны нәтиҗәле файдалануның фәнни һәм гамәли нигезләрен эшләү; агынты суларны чистарту технологияләрен эшләү; ТРның аеруча саклаулы табигать терр-яләре системасын камилләштерү; респ-ка автоматлаштырылган экологик мәгълүмат базасын булдыру; углеводород чималының яңа ятмаларын һәм чыганакларын ачыклау; геологик разведкалау эшләренең нәтиҗәлелеген арттыру; углеводород чималы чыганакларын эзләү, разведкалау һәм эшкәртү ысулларын оптимальләштерү һәм камилләштерү; энергетика һәм табигый ресурсларга караган законнар эшләүне камилләштерү һәм үстерү. 2013 тән ин-тта ЮНЕСКОның «Тотрыклы бергәлек төзү өчен Җир Хартиясенең фундаменталь принципларын үстерү» кафедрасы эшли. Институт белгечләре тарафыннан ТРның экологик иминлеген тәэмин итү буенча мөһим фәнни проектлар тормышка ашырыла: нефть продуктлары һәм авыр металлар микъдары буенча туфракларның төбәк сыйфат нормативлары эшләнә; ТРда органик а.х. продукциясе җитештерү системасы эшләнә; атм. һавасының сыйфатын контрольдә тоту өчен атмосфераның пычрану чыганаклары буенча автоматлаштырылган мәгълүмат базасы булдырыла; Түбән Кама сәнәгать төененең әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә тискәре техноген тәэсирен бәяләү һәм фаразлау эше башкарыла; ТР су хуҗалыгы комплексының максатчан үсеш программасы эшләнә; сәнәгать пр-тиеләренең җир өсте сулары сыйфатына йогынтысына эксперт бәя бирелә; ТРның Кызыл китабы («Красная книга РТ»), «ТР туфракларының Кызыл китабы» («Красная книга почв РТ»), «ТРның аеруча саклаулы табигать территорияләре дәүләт реестры» («Государственный реестр ООПТ в РТ»), «ТР буйлап экологик экскурсия» («Экологический гид по РТ») басмалары әзерләнә һәм басылып чыга. Институт белгечләренең тәкъдимнәре буенча девон-ташкүмер утырмаларында дүрт нефть чыганагы ачыла. Институтта «экология» һәм «гражданнар хокукы, эшмәкәрлек хокукы, гаилә хокукы, халыкара шәхси хокук» белгечлекләре буенча аспирантура бар. Директоры — Р.Р.Шаһидуллин.

**ЭКСЛИ́БРИС** (лат. ex libris — китаплардан), китапның аерым кешегә, китапханәгә, китап кибетенә мөнәсәбәтле булуын раслаучы сәнгатьчә бизәлгән тамга, ярлык. Россиядә Э.ның беренче үрнәкләре — кулъязма китапларда иясен таныклаучы яисә әченә куеп калдырылган аерым битләрдәге язмалар 15 йөз ахырыннан билгеле. Китап басу барлыкка килгәннән соң, суперэкслибрислар — нәсел тугралары, вензельләр, монограммаларның тышлыкка басып төшерелгән нәфис сурәтләре тарала башлый. Россиядә тышлыкның эчке ягына ябыштыру өчен кәгазьгә басылган күбесенчә тугралы һәм шрифтлы Э.лар — 18 йөзнең

1 нче чирегендә, вензельле, ш.и. китапның титул битендәге рельефлы буяусыз басма Э.лар — 18 йөз уртасында, виньеткалар, политажлар һ.б. кечкенә җыелма формалар кергән басмаханә ысулы б-н башкарылган сюжетлы-орнаментлы, шрифтлы Э.лар 19 йөздә барлыкка килә. Китап хуҗасының фамилиясен язу өчен буш урын калдырылган универсаль Э.лар, ш.у. каучук мөһердән буяу б-н төшерелгән Э. лар да очрый.

Басмаханә ысулы б-н кысага алынган шрифтлы «Инихов һәм Базунов кибетеннән» («Из лавки Инихова и Базунова», Казань) Э.ы һәм ш.у. берничә шрифт төре кулланылган «Андрей Мясниковның Казандагы Воскресенский ур. урнашкан китапханәсеннән уку өчен, бүлек №» («Из библиотеки для чтения Андрея Мясникова, состоящей на Воскресенской ул. в Казани, отделение №») Э.ы 19 йөзнең 1 нче яртысына карый. Бугсгевден нәселе китапханәсендәге китаплар тугралы, буяулар кулланылган басма Э.лар б-н тамгаланганнар. Казан дворяннары Булыгиннарның тугралы Э.ында «Языково авылы, бүлек №» («Сельцо Языково, отделение №») дигән язу була. Коллекционер Лихачёв китапханәсендә вензельле буяусыз коры басма ысулы б-н төшерелгән берничә Э., ш.у. кыса эченә «А.Ф.Лихачёв милке» («Принадлежит А.Ф.Лихачёву») дип язылган басмаханә ярлыгы саклана. Сәүдәгәр, нумизмат, кульъязмалар һәм әүвәлге басма китаплар тупланмасы хуҗасы Ф.Т.Васильев «Ф.Т.Васильев китаплары тупланмасыннан, №, шкаф, шүрлек» («Из собрании книг Ф.Т.Васильева №, шкаф, полка») дип язылган борынгы кульъязма рәвешендәге Э.тан файдалана. Казан тарихының танылган белгече Н.Я.Агафонов ташбасма ысулы б-н эшләнгән, битләренә «Николай Агафонов китапханәсе. Китаплар һәм кульъязмалар каталогы. Бүлек №» («Библиотека Николая Агафонова. Каталог книг и рукописей. Отд. №») дип язылган ачык китап сурәте төшерелгән чәчәк орнаментлы озынча түгәрәк кыса эченә алынган Э.ка ия була.

19–20 йөзләр чигендә эстамп, авторлык графикасы сәнгате һәм китаплар һәвәскәрлеге күтәрелеше Э.ның сәнгати һәм коллекционерлык әһәмиятенә ия кечкенә формалы графиканың мөстәкыйль төре булып әверелүенә этәргеч бирә. Э.ның эмблема рәвешендә китапханә хуҗасының холкын һәм эшчәнлеген чагылдыручы тарихи-сәнгати һәм китапчылык мәгълүмат чыганагы буларак әһәмияте арта. Мәс., китап тамгаларын җыючы казанлы С.Гордеевның модерн стилендәге Э.ына елан уралган гыйлем агачы янында тасвирланган Һаува рәсеме, «ex libris» һәм «Sergeii Gordeiev» тексты төшерелгән. 20 йөз башында Казан, Саратов, Вологда, Киев шәһәрләре б-н берләттән, Э. сәнгате нык үсеш алган үзәкләрнең берсе санала. Казан рәссамнарының «Всадник» коллективы, нигездә, Ленинград экслибристлар җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы, П.Е.*Корнилов* башлангычында Э. сәнгатен торгызуга сизелерлек өлеш кертә. Китап миниатюралары төп автор нөсхәсе басмасыннан чикләнгән күләмдә басылалар һәм еш кына иҗат фантазиясен, график стильләштерүләрне, буш яки символик композицияләрне күрсәтү өчен сылтау булып кына хезмәт итәләр. «Китап тамгалары. I чыг. А.Платунова, К.Чеботарёв» («Книжные знаки. Вып. I. А.Платунова, К.Чеботарёв», 1922) басмасында тупланган һәм линогравюра техникасында 50 данә тираж б-н басылган 13 Э. шундыйлардан. П.Е.Корнилов өчен Казан шәһәренең архит-ра истәлекләре төшерелгән аерым китап тамгаларын рәссамнар Д.И.Архангельский, В.Э.Вильковисская, А.Г.Платуновалар эшләп бирә. 1923 елда Казан сәнгать-техника ин-ты остаханәсе көче б-н 19 йөзнең 1 нче яртысында күчереп ясалган Казан Э.лары һәм 20 йөз башы төп литографик нөсхәләр кергән җыентык басылып чыга. Шул ук елда 256 Э., ш.и. П.Е.Корнилов тупланмасыннан Казан рәссамнары әсәрләре дә куелан «Рус китабы тамгасы» («Русский книжный знак») күргәзмәсе була (ТАССР Үзәк музееның гравюралар кабинеты оештыра). 1930–50 елларда Э. б-н кызыксыну тар белгечләр даирәсендә генә саклана. 1950 еллар ахырыннан Э.ка рәссамнар Б.М.Столбов, Г.И.Сотонина, В.А.Шолпо, В.А.Дайчманнар мөрәҗәгать итә. Э. тупланмалары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Казан федераль ун-тының Тарих музеенда, шәхси тупланмаларда сакланалар.




**Экслибрислар:** 1. Ш и л л и н г о в с к и й П.А. ТАССР Үзәк музее китапханәсе. Ксилография. 1926; 2. Ч е б о т а р ё в К.К., П л а т у н о в а А.Г. Кәгазь. Линогравюра. 1922; 3-4. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы татар экслибрислары үрнәкләре. Авторлары билгесез.

*Әд.:* К о р н и л о в П.Е. Казанский книжный знак // Казанский библиофил. 1923. № 4; К л ю ч е в с к а я Е.П. Архитектурные мотивы в экслибрисах Петра Корнилова // Дизайн и новая архитектура. 2004. № 15/16.

*Е.П.Ключевская.*

**ЭКСПЕРИМЕНТА́ЛЬ ФОНЕ́ТИКА**, аерым телләргә, ш.у. тел семьялыкларына хас сөйләм авазларының акустик табигатен, телдәге аваз төзелеше күренешләрен инструменталь ысуллар ярдәмендә өйрәнүче гамәли *фонетика* бүлеге. Э.ф.га *Казан лингвистика фәнни мәктәбе* вәкилләре, аерым алганда, И.А.*Бодуэн де Куртенэ* тарафыннан нигез салына. 19 йөз ахырында Казан ун-тында Э.ф.кабинеты (соңрак лаб-я статусы ала) оештырыла, җитәкчесе В.А.*Богородицкий* була. 1880 елда ул рус телендә беренче «Рус телендә басымсыз сузыклар» («Гласные без ударения в русском языке») эксперименталь-фонетик хезмәтен нәшер итә, 1896–1907 дә «Эксперименталь фонетика буенча күзәтүләр» («Заметки по экспериментальной фонетике», чыг. 1–5) сериясе басыла. Аның «Эксперименталь мәгълүматлар яктылыгында татар орфографиясе һәм әйтелеше турында күп кенә экскурслар һәм рәсемнәр белән рус теле фонетикасы бирелеше» («Фонетика русского языка в свете экспериментальных данных со многими рисунками и экскурсами о татарской орфографии и произношении», 1930) һәм «Башка төрки телләр белән бәйле рәвештә татар тел белеменә кереш» («Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками», 1934) хезмәтләрендә татар Э.ф.сы тирәнтен тикшерелә. Аның шәкерте һәм дәвамчысы Г.Ш.Шәрәф бу юнәлештә актив һәм уңышлы эшли. Татар теле авазлары палатограммаларын анализлап һәм татар сузыкларының сонор озынлыгын өйрәнеп, ул татар телендәге авазларны инструменталь өйрәнү методикасын эшләп чыгара. Соңрак бу аспектлар Ү.Ш.Байчураның «Татар теленең авазлар төзелеше» («Звуковой строй татарского языка»; 1–2 кис., 1959–61) хезмәтендә фәнни тасвирлау предметына әверелә. Татар телендә иҗек төзелешен тәҗрибә юлы б-н өйрәнү Т.И.Ибраһимовның күпьеллык тикшеренүләре предметы була. 1970–90 елларда Х.Х.Сәлимов татар сузыкларына спектраль анализ уздыра, соңрак татар сөйләме просодиясен өйрәнә. Э.ф. ысуллары Ш.Н.Асылгәраев, М.Х.Бакиров, Р.М.Балтаева, Г.М.Сөнгатов һ.б.ның хезмәтләрендә файдаланыла. 20 йөз ахырында ТР ФА һәм Казан ун-ты б-н берлектә ясалма интеллект лаб-ясе оештырыла, анда татар сөйләме синтезаторы эшләнә (авторлары Җ.Ш.Сөләйманов, Т.И.Ибраһимов, Ф.И.Сәлимов, Р.Р.Хөсәенов, М.Р.Сәйхунов), төрле төрдәге җөмләләрнең интонацион контурларын модельләштерү буенча эшләр алып

барыла, сөйләм авазы параметрлары б-н идарә итү программалары төзелә, шәхесне тавышы аркылы тану, татар теле диалектларын өйрәнү проблемалары карала. Эшләнгән ысуллар, алгоритмнар һәм төрле программалар чит телле аудиториядә татар телен укытуда актив кулланыла.

*Әд.:* Артёмов В.А. Экспериментальная фонетика. М., 1956; Экспериментальная фонетика. М., 1989; Гордина М.В. История фонетических исследований (от античности до возникновения фонологической теории). СПб., 2006; Овчинникова И.Г., Угланова И.А. Компьютерное моделирование вербальной коммуникации. М., 2009; Губайдуллина Г.Т. Татарская экспериментальная фонетика: истоки и этапы её развития: Автореф. дис. ... К., 2011.

*Р.Ә.Колшәрипова.*

**ЭКСПЕРИМЕНТА́ЛЬ ФОНЕ́ТИКА КАБИНЕТЫ́**, Казан ун-ты каршында, 1880 елларда В.А.*Богородицкий* тарафыннан оештырыла. 1882–84 тә ул Розапелли приборы, Вердэн кимографы, Гуцман пневмографы, Руселло бугаз капсулалары һ.б. ярдәмендә сөйләм авазларының физик һәм физиол. үзенчәлекләрен өйрәнү омтылышы ясый. Экспериментал тикшеренүләр методикасы авазларның әйтелеш динамикасын, артикуляциянең физик-акустик ягын комплекслы тасвирлау мөмкинлеге бирә. Аларны өйрәнү уку-укыту программасына кертелгән «Экспериментал фонетика» дисциплинасының эчтәлеген тәшкил итә. 1896 да Богородицкий «Экспериментал фонетика буенча язмалар» («Заметки по экспериментальной фонетике», 1–5 чыг., 1917 гә кадәр басыла) җыентыгын чыгара башлый. 1914 тә Гамбург шәһәрендә уздырылган Халыкара экспериментал фонетика съездында уңышлы чыгыш ясый. 1920 дә Э.ф.к.на Мәскәү пед. чит телләр ин-ты каршында экспериментал фонетика лаб-ясен оештырган В.А.Артёмов килә. Э.ф.к.нда уздырылган экспериментал тикшеренүләр рус теленә генә түгел, татар һәм башкорт телләренә дә карый. Бу кабинетта Богородицкий үзенең тикшеренүләре нәтиҗәсе буенча 1920 дә текстларга рәсемнәр атласы бирелгән «Рус әдәби телендә авазлар әйтелешенә мөнәсәбәтле экспериментал фонетика курсы»ның («Курс экспериментальной фонетики применительно к литературному русскому произношению») бернечә чыгарылышын бастыра. Анда әйтелешнең анатомик-физиол. һәм физик-акустик үзенчәлекләрен экспериментал фонетик яктан өйрәнү ысуллары һәм алымнары җентекле тасвирланган. Аның «Татар орфографиясе һәм татар авазлары әйтелеше хакында экскурс һәм рәсемнәрдән торган рус теле фонетикасы экспериментал мәгълүматлар яктылыгында» («Фонетика русского языка в свете экспериментальных данных со многими рисунками и с экскурсами о татарской орфографии и произношении», 1930) хезмәте сөйләм авазларын экспериментал-фонетик өйрәнү үрнәге булып тора. Богородицкий шәкерте Г.Шәрәфнең «Татар сузыкларының сонор озынлыгы» («Сонорная длительность татарских гласных», 1928) хезмәте ватан һәм чит ил тюркологлары арасында танылу таба. Э.ф.к. хезмәткәрләре сөйләшләр, фольклор әсәрләре фонетикасын тикшерәләр: 100 гә якын татар, башкорт, мордва, мари җырлары язып алына һәм нотага салына; «Сигез татар-башкорт җыры» («Восемь татарско-башкирских песен», 1923) җыентыгы һәм мари халкының беренче «Чирмеш җырлары җыентыгы» («Сборник черемисских песен», 1908) басыла. Кабинетта М.И.Берг, Н.Ф.Катанов, А.А.Эйхенвальд шөгыльләнә; еш кына Г.Тукай да килә. 1930 елларда Казан ун-тында тарих-филол. ф-ты ябылу б-н бәйле рәвештә, Э.ф.к. эшләүдән туктый, аппаратура һәм китапханә Казан пед. ин-тына күчерелә. 1950 елларда Э.ф.к.н торгызу эшенә Л.В.*Златоустова* тотына. Диалектологик тикшеренүләр, беренче чиратта рус теле сөйләшләрен өйрәнү эшләре алып барыла. 1970 елларда кабинетның фәнни җитәкчесе З.М.Әлмөхәммәдова була. Э.ф.к.нда рус сөйләшләре б-н беррәттән татар әдәби теле, ш.у. шигъри тел буенча экспериментал фонетик тикшеренүләр уздырыла. 1990 елларда кабинет теоретик һәм гамәли лингвистика кафедрасы каршындагы *гамәли лингвистика һәм экспериментал фонетика лабораториясенә* үзгәртелә (фәнни җитәкчесе — проф. К.Р.Галиуллин).

*Әд.:* Ершов С.И. Экспериментальная фонетика. К., 1903; Богородицкий В.А. Очерки по языковедению и русскому языку. К., 1910; Шул ук. Лекции по общему языкознанию. К., 1913; Артёмов В.А. Экспериментальная фонетика. М., 1956; Аристов В.В. Страницы славной истории. К., 1987.

*Р.Ә.Колшәрипова.*

**ЭКСПРЕССИОНИ́ЗМ**, (лат. expressio — гәүдәләндерү), 20 йөзнең 1 нче чирегендә Көнбатыш Европа әдәбияты һәм сәнгатендәге агым. Э. бердәнбер чынбарлык дип кешенең субъектив рухи дөньясын, ә аны чагылдыруны — сәнгатьнең төп максаты дип игълан итә. Гаять кискен социаль кризиска (Беренче бөтендөнья сугышы, революцион тетрәнүләр) җавап рәвешендә барлыкка килә. «Э.» терминын беренче тапкыр (1911) матбугатта немец язучысы һәм авангард сәнгать пропагандисты Г.Вальден куллана. Э. принциплары аеруча Германия һәм Австрия сәнгатендә үсеш ала. Э.ның чынбарлыкны трагик тою, эмоцияләрне белдерүнең киеренкелеге, образларның иррациональлеге кебек билгеләре 20 йөз башы татар әдәбиятындагы *гыйсъянчылык* агымына хас. Уй-фикерләрне тәэсирле итеп гәүдәләндерү кебек Э. алымнары («экспрессияләр») С.Рәмиев, Һ.Такташ, Ш.Бабич һ.б. шагыйрьләрнең гыйсъянчылык шигырьләрендә аеруча роль уйныйлар. Экспрессионистик характер Н.Думавиның 1910 еллардагы күпчелек шигырьләренә хас. Аларның үзәгендә — социаль катаклизмнардан интегеп беткән милли җәмгыять вәкиле; автор өчен әһәмиятле идеяне белдерүгә арттырулар һәм шартлылыклар юлы б-н ирешелә. Э. билгеләренең активлашуы 20–21 йөзләр чигендә Зөлфәт, Р.Зәйдулла һ.б. поэзиясендә күзәтелә.

*Әд.:* Ганиева Р.К. Татарская литература: традиции, взаимосвязи — Татар әдәбияты: традицияләр, бәйләнешләр. К., 2002; Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007; Литературная энциклопедия терминов и понятий. М., 2001.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**«ЭЛА́СТИК»**, полимер материаллар җитештерүче завод. Түбән Кама шәһәрендә урнашкан. 1984 елда «Түбәнкаманефтехим» ЖБ составында халык куллануы товарлары эшләп чыгару өчен оештырыла, 1991 дән арендадагы пр-тие, 1993 тән җаваплылыгы чикләнгән ширкәт, 1998 дән АҖ, 2004 тән «Э. за-








«Эластик» заводы эшләнмәләре. 1. Тукылмаган пропилен материалдан эшләнгән бер кулланышлы медицина киеме. 2. Сиптерү шланглары. 3. Полимер-текстиль һәм коеп ясалган аяк киеме.

воды» ҖЧҖ. Эшләүчеләр саны — 300 дән артык кеше (2015).

Заводның беренче продукциясе резина һәм спорт аяк киемнәре була. 3 завод корпусы төзелә. Тулы куәтенә ирешкәч, илдә тиңдәшләре арасында иң эре пр-тиеләрнең берсенә әверелә: еллык җитештерү күләме 7 млн. пар аяк киеме, эшләүчеләр саны 1200 кеше тәшкил итә. 1987 дә — линолеум, юыла торган обойлар, 1990 елларда — пластмасса эшләнмәләр, япма материал, буяулар, 2004 тә — полимер капламлы эшләнмәләр, 2006 да тукылмаган материаллар эшләп чыгару башлана. 2010 да «Э.» җирлегендә мед. өлкәсендә бер кулланылышлы кием һәм урын-җир әйберләре эшләү өчен киң колачта яңа буын күп катламлы тукылмаган полипропилен материаллар чыгару буенча Россиядә беренче ябык цикллы терр.-җитештерү кластеры төзелә (ш.у. Казандагы «Здравмедтех-Поволжье» компаниясен дә үз эченә ала). 2011 дән, башкаручыларның берсе буларак, завод «2020 елга кадәрге чорда Россия Федерациясенең фармацевтика һәм медицина сәнәгате үсеше» федераль максатчан программасында катнаша.

Пр-тиедә продукциянең 150 дән артык төре: поливинилхлорид пластикаттан коелган (галошлар, итекләр) һәм полимер-текстиль (итекләр, ботинкалар, спорт туфлиләре) аяк киемнәре, медицинада, а.х.нда (каплау материалы), төзелештә (диварлар һәм түбәләр изоляциясе), йорт җиһазлары (катламнар, тышлыклар), тегү (эчлек, ялгаулар) сәнәгатьләрендә кулланылучы күп катламлы тукылмаган полипропилен материаллар, пластмасса эшләнмәләр (чиләкләр, әрҗәләр һ.б.), поливинилхлорид пластикат сиптерү шланглары, полимер капламлы саклану чаралары (бияләйләр, перчаткалар, киез итекләр), япма материал һәм аннан ясалган эшләнмәләр (япмалар, чатырлар һ.б.), поливинилхлорид пластикат, буяулар, ингибиторлар җитештерелә. Продукция халыкара EN 13795:2011, ИСО 9001–2008 стандартларына туры килү сертификатларына ия.

Завод Италия, Германия, Австрия фирмалары тарафыннан җитештерелгән кою агрегатлары, термопластавтоматлар, технол. линияләр, тегү, кисү, пресслау, катнаштыру җиһазлары, экструдерлар, бөртекләндерү җайланмалары б-н коралландырылган.

Пр-тие җитәкчеләре арасында — И.Х.Хафизов, Р.Т.Галимов, Д.А.Шемякин, В.А.Шакиров (2014 тән).

**ЭЛЕВА́ТОР**, күп күләмдә бөртекле ашлык саклау һәм аны тиешле сыйфатка җиткерү өчен кабул итү, үлчәү, киптерү, чистарту, бөртекле ашлыкны автомобиль, тимер юл, су транспортына төяп җибәрү җайланмалары б-н җиһазландырылган пр-тие. Э. силос тибындагы — монолит яки җыелма тимер-бетон, планда түгәрәк, төп технол. һәм транспорт җайланмалары урнаштырылган эш бинасы б-н кушылып, корпусларга берләштерелгән сыешлыклардан (силослардан) гыйбарәт ашлык саклау урынын үз эченә ала. Ашлык кабул итү бункерларыннан транспортёрлар ярдәмендә эш бинасының өске өлешенә күтәрелә, үлчәнә, кушылмалардан чистартыла, ашлык киптергечләрдә киптерелә һәм өске конвейр буйлап силос өстендәге транспортёрларга җибәрелә, транспортёрлар ашлыкны силосларга төшерәләр. Ашлыкны силослар төбендәге бүрәнкәле тишекләр аша силослар астындагы конвейерларга бушаталар. Силослар ашлыкны дезинфекцияләү һәм актив җилләтү җайланмалары, темп-ра үлчәү өчен термик асылмалар б-н җиһазландырыла. Заманча эре Э.ларда машиналар һәм механизмнар б-н идарә итү автоматлаштырылган, телевизион җиһазлар кулланыла.

Беренче силослы элеватор АКШта (Дулут ш.) 1845 елда, Россиядә 1887 дә (Түбән Новгород ш.) барлыкка килә, Татарстан терр-ясендә 1914–17 дә Дәүләт банкы хисабына *Бөгелмә элеваторы* һәм *Чаллы элеваторы* төзелә. 1930 елларда Арча, Кукмара, Норлат, Ютазы, 1960 елларда Казан порты һәм *Чистай элеваторлары*, 1980 елларда Буа һәм Борындык (респ-када иң эресе, елга 160 мең тонна ашлык кабул итүгә исәпләнгән), 2000 елларда Әлки, Мулла Иле (Яшел Үзән р-ны), Левашево (Алексеев р-ны) Э.лары һ.б. корыла. ТРда барлыгы 15 Э. бар; аларда респ-ка товарлыклы ашлыгының 50% ы чамасы, ш.и. барлык дәүләт интервенция фонды саклана. ТРдагы эре Э.лар каршында ашлыкны эшкәртү һәм он, ярмалар, терлек азыгы җитештерү куәтләре эшли.

*Г.Я.Мәүлетова, С.Г.Белов.*

**ЭЛЕ́ГИЯ**, (грек. elegéia — сагышлы җыр), лирик поэзия жанры, фани дөнья, кеше гомеренең кыскалыгы турында фәлсәфи уйлануларны үз эченә алган эмоциональ эчтәлекле зур булмаган шигырь. Татар поэзиясендә Г.Тукай («Өзелгән өмид»), М.Гафури («Кайвакытта»), Ш.Бабич («Аптыраган минутларда»), Р.Әхмәтҗанов («Сибгат ага Хәкимгә элегия»), Ә.Мәхмүдов («Мәңгелек моң»), Р.Гатауллин («Элегия») иҗатларында чагыла.

*Т.Н.Галиуллин.*

**«ЭЛЕКО́Н ЗАВОДЫ́»**, электроника сәнәгате пр-тиесе. Казанда урнашкан. Эшләүчеләр саны — 4100 кеше (2017). 1939 елда Казан авиация з-дының калориферлар производствосы җирлегендә җылылык алмашу приборлары з-ды буларак оештырыла. Җитештерү һәм торак биналарын җылыту өчен радиаторлар (калориферлар) чыгара. 1941 нең ахырында Мәскәүдән эвакуацияләнгән электромеханика з-ды б-н кушылганнан соң җитештерү күпкә киңәя. Танклар, автомобильләр һәм самолетлар өчен радиаторлар, бензин баклары, ялкынсыз горелкалар, патроннар һәм сапер инструментлары өчен савытлар, кул гранаталары һәм авиация бомбалары детальләрен, формалы кием өчен фурнитура эшләү җайга салына. Аэронавигация приборлары өчен даими кулланылулы яктылык составын җитештерү буенча махсус лаб. оештырыла; яктылык массасын эшләү һәм җитештерү Казанга эвакуацияләнгән академиклар С.И.Вавилов, В.Г.Хлопин җитәкчелегендә башкарыла. Сугыштан соңгы беренче елларда завод төзелештә файдаланыла торган торбадан төзелеш күперчекләре, кирпеч ташу өчен контейнерлар, металл арбалар, диафрагма насослары, генераторлар, электр һава өрдергечләре, транспортёрлар, калориферлар, комбайннар өчен чылбырлар җитештерә. 1950 дә электр тоташтыргычлары җитештерүгә күчерелә һәм Казан штепсельләр з-ды (296 нчы п/я оешмасы) итеп үзгәртелә. Пр-тие киңәйтелә, аңа реконструкция уздырыла, яңа производстволар оештырыла, заманча махсус технол. җиһазлар урнаштырыла. 1954 тә махсус инженерлык хезмәте булдырыла һәм радиотехник аппаратура — самолетларның тану-ачыклау системаларын, авиация өчен бортта һәм җир өстендә урнаштырыла торган радиомаякларны эшләп чыгару башлана; 1959 да ракета-галәм техникасы өчен телеметрик һәм ерак араларны үлчәгеч аппаратура («Рубин», «Алмаз» эшләнмәләре) җитештерү үзләштерелә; 1961 дә беренче канатлы ракеталар б-н идарә итү өчен «Парус» системасын, старт алдыннан борттагы аппаратураны контрольдә тоту комплексын, дөньяда беренче идарә ителүче «Восток» космик корабле өчен аппаратура комплектын эшләп чыгару җайга салына. Шул ук елда хөкүмәт куйган бурычларны үрнәк рәвештә башкаруы, яңа техника эшләп чыгаруы һәм электроника сәнәгатен алга җибәрүгә керткән өлеше өчен пр-тие Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. 1966 да завод Казан радиокомпонентлар з-ды итеп үзгәртелә. 1967 дә шәһәр тибындагы Уруссу поселогында заводның ныклы герметик тоташтыргычлар чыгаручы ф-лы оештырыла. 1976 да завод ҖБ статусын ала. 1980 елларда анда катлаулылык дәрәҗәсеюгары булган «Электроника Б1–01» стереофоник электрофоннарының, технол. процесслар б-н идарә итү өчен махсуслаштырылган «Электроника ДЗ–28» микро электрон хисаплау машиналарының (ЭВМ), өстәл ЭВМнарының, көнкүреш компьютерларының һ.б.ның проектлары эшләнә һәм аларны җитештерү җайга салына. 1991 дә пр-тие лазер. мед. җайланмаларын һәм приборларын, ш.у. җепселле-оптик инструментларны, машиналар төзелеше эшләнмәләрен, бикләвеч арматура чыгара. 1995 тә ул «Элекон» ФҖБ итеп үзгәртелә, аның составына Казан радиокомпонентлар з-ды (баш пр-тие), цилиндрлы тоташтыргычлар фәнни-тикшеренү ин-ты (1953 тә нигезләнгән Аерым цилиндрлы тоташтыргычлар КБ җирлегендә 1989 да Казан штепсельле аергычлар КБ буларак оештырыла) һәм Уруссу «Электросоединитель» з-ды керә. 1999 дан — «Элекон заводы» АҖ. Төп продукциясе: электр тоташтыргычлары, төрле төр аэрокосмик, диңгез, автомобиль, сәнәгать өчен аергычлар һ.б. Заводның Спорт йорты, балыкчы һәм сунарчы базасы, ял базасы бар. Күп кенә хезмәткәрләре хөкүмәт бүләкләренә лаек була: 6 кеше — ТРның Дәүләт бүләге лауреаты, 2 кешегә — Соц. Хезмәт Герое, 16 кешегә — РФнең атказ. машина төзүчесе, 18 кешегә — ТРның атказ. машина төзүчесе, 2 кешегә — ТРның атказ. икътисадчысы, 1 кешегә — РФнең атказ. юристы, 3 кешегә РФнең атказ. уйлап табучысы исе-

ме бирелә; 17 кеше — Ленин ордены, 14 кеше — Октябрь Революциясе, 121 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 199 кеше — «Почет билгесе», 163 кеше — 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Хезмәт даны, 5 кеше Дуслык орденнары, 445 кеше медальләр б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәкчеләре — В.Л.Голованов (1939–42, 1946–49), Х.Г.Датиев (1942–46), И.Н.Максимов (1949–60), В.И.Самарин (1960–62), Л.В.Гыйзәтдинов (1962–82), А.И.Лебедев (1982–86), А.И.Ларюшин (1986–97), Н.А.Колесов (1997–2007), А.Н.Колесова (2007–10), Н.Н.Ураев (2010 нан).

*Әд.:* Махмутова А. Три рождения и пять названий «Элекона» // Казань. 1999. № 1/2.

*Р.К.Мингалиев, Г.Я.Мәүлетова.*

**ЭЛЕ́КТР ЭНЕРГЕ́ТИКАСЫ**, сәнәгатьнең электр энергиясен эшләп чыгаручы, тапшыручы һәм бүлүче тармагы; фәнни-техник алгарышны тәэмин итүдә гаять мөһим роль уйный. Э.э. үсеше генерацияләүче куәтләрне һәм электр энергиясе җитештерү күләмен үстерү, электр челтәрен киңәйтү, ш.и. электр тапшыру линияләренең (ЭТЛ) озынлыгын һәм көчәнешен, трансформатор подстанцияләренең исәбен арттыру, техник процессларны һәм җиһазларны камилләштерү юлы б-н гамәлгә ашырыла. Татарстан терр-ясендә Казандагы (шәһәр электр станциясе, 1895–1926 елларда эшли; трамвай өчен электр станциясе, 1898–1928), Алабугадагы (1902), Чистайдагы (1913), Мамадыштагы (1914), Бөгелмәдәге (1917) беренче даими ток электр станцияләре электр энергиясен почтага, телеграфка һәм телефонга, үзәк урамнарны, дәүләт учреждениеләре бүлмәләрен, җәмәгать биналарын, уку йортларын, бай хуҗаларның йортларын яктырту өчен тапшыралар. Электр генераторлары һәм электр җиһазлары Казандары з-дында (даими ток — 1887 дә, алмаш ток — 1915 тә), бертуган Крестовниковларның сабын кайнату з-дында, Алафузовлар, Акчурин, Сәйдәшев, «Поляр» ф-каларында, Паратск суднолар ремонтлау остаханәләрендә, Чаллы элеваторында, Бондюг химия з-дында урнаштырыла.

Совет хакимияте елларында Э.э. үсеше халык хуҗалыгының өстенлекле бурычларының берсенә әверелә (к. *ГОЭЛРО*, *Электрлаштыру*). Казан политехник ин-тында энергетика белгечләре әзерләү башлана (1919 дан), тармакның үзәкләштерелгән идарә органнары — Татарстан ХХСның электр техникасы сәнәгате бүлеге (1920), Казан «Эльводтрам» тресты (1924) оештырыла. Алабугада (1920), Минзәләдә (1922), Казанда (1915 тә нигезләнә, 1925–42 дә эшли), Бөгелмәдә һәм Тәтештә (1927) алмаш ток электр станцияләре корыла. 1925–27 дә Казан шәһәр электр челтәрләре киңәйтелә, югары вольтлы һава линияләре кабельле линияләргә алыштырылып, 6 *кВ* га кадәр көчәнешле өч фазалы алмаш токка күчерелә. Торак йортларны электрлаштыру, шәһәр читләрен яктырту, сәнәгать пр-тиеләрен үзәкләштерелгән электр тәэминатына тоташтыру эшләре җәелдерелә. 1930 еллар — 1940 еллар башында ТАССРда тизләтелгән *индустрияләштерү* өчен энергетика базасы төзелә башлый. 1931 дә «*Татэнерго*» идарәсе оештырыла. Алдынгы техника һәм технологияләр нигезендә 1 нче (1933) һәм 2 нче (1938) *Казан җылылык-электр үзәкләре* (КТЭЦ) төзелә. Аларны эшләтеп җибәрү нәтиҗәсендә Казанның гамәлдәге һәм төзелүче пр-тиеләре тулысынча электр б-н үзәкләштерелгән тәэмин ителүгә күчәләр, күп кенә торак массивлар электрлаштырыла. Подстанцияләре б-н 35 *кВ* көчәнешле ЭТЛ төзелә башлый (беренчесе — КТЭЦ-1-Елга аръягы 1933 тә). Казаннан электр энергиясе ш.у. Яшел Үзән шәһәренә (1934), Мари АССРга (1935), Юдино станциясенә (1940), Дербышки бистәсенә (1941) тапшырыла. Авылларны электрлаштыру башлана: Тәтеш (1934), Арча һәм Мамадыш (1937) р-ннарында кече елгаларда егәрлекләре зур булмаган беренче колхоз ГЭСлары төзелә.



ТР энергетика системасының үзәк диспетчерлык залы.

Бөек Ватан сугышы чорында ТАССР терр-ясенә эвакуацияләнгән сәнәгать пр-тиеләрен оператив рәвештә электр энергиясе б-н тәэмин итү мәсьәләсе хәл ителә. 1944 тә энергетика объектларын кору өчен беренче «Казэнергострой» махсуслаштырылган тресты оештырыла.

1940 елларның 2 нче яртысы – 1950 елларда респ-када Э.э.ның интенсив үсеше, башлыча, нефть чыгару сәнәгатен булдыру һәм аның үсеше б-н бәйле. 1944 тә Урыссу ГРЭСы төзелә (УГРЭС, киңәйтелү эшләре 1957 дә тәмамлана). Подстанцияләре б-н бергә 35 *кВ* көчәнешле Урыссудан Башкортстан АССРдагы Туймазы нефть промыселларына (1944–45) һәм Октябрьский шәһәренә (1948), Баулы авылына (1948) кадәрге, 110 *кВ* көчәнешле Урыссу–Бөгелмә–Яңа Писмән (1952, ТАССРда беренче) ЭТЛләре, Урыссу–Бөгелмә–Яңа Писмән–Әлмәт–Азнакай–Урыссу боҗрасы (1954), Урыссу энергетика төйнәлешен Башкортстанның Әлмәт–Зәй энергетика системасы б-н тоташтыручы Урыссу-Дим ЭТЛ (1955) корыла. 1958–59 да 400 *кВ* (соңрак 500 *кВ*) көчәнешле Идел ГЭСы-Бөгелмә-Бекетово транзит ЭТЛ һәм Бөгелмә подстанциясе (илдә иң эреләрнең берсе) файдалануга тапшырылгач, Урыссу төйнәлеше СССРның Европа өлеше Бердәм энергетика системасы (БЭС) һәм Урал энергетика системасы б-н тоташтырыла. Нефть промыселларын, төзелүче торак пунктларны тоташ электрлаштыру бара (ел саен ТАССРның нефть чыгарылучы районнарында 2000 *км* га кадәр озынлыкта ЭТЛ, 6–0,4 *кВ* көчәнешле 1,5 меңләп трансформатор подстанцияләре, 20 гә кадәр 35–110 *кВ* көчәнешле подстанция гамәлгә кертелә).

1950 елларда яңа турбиналар һәм казаннар урнаштыру нәтиҗәсендә Казан энергетика төйнәлешендә 1 нче һәм 2 нче КТЭЦларның генерацияләү куәте 2 тапкыр арта. Көнчыгыш подстанция (Арча) (1948), Казаннан Васильево поселогына кадәрге ЭТЛ-35 *кВ*, Яшел Үзән, Йошкар-Ола һәм Чабаксар шәһәрләренә кадәрге ЭТЛ-110 *кВ* (1958–59) файдалануга тапшырыла.

1946 да «Татсельэлектро» респ-ка проектлау-төзелеш-эксплуатацияләү конторасы оештырылганнан соң, авылларны электрлаштыру эше активлаша. Ык елгасында респ-када беренче Яңа Мәлкән дәүләт ГЭСы (1952), Зөя елгасында Апас р-нында колхозара Дәвеш (1957) һәм Буа р-нында Кыят (1959) ГЭСлары төзелә. Ш.у. массачыл рәвештә а.х. объектларын югары көчәнешле дәүләт челтәрләренә тоташтыру башлана. 1956–60 та Чыпчык, Арча, Дөбъяз, Комлы Кавал, Питрәч торак пунктларында респ-када беренче а.х. билгеләнешле 35 *кВ* көчәнешле подстанцияләр корыла. Нәтиҗәдә 1950–60 елларда электрлаштырылган колхозларның өлеше 7% тан 55% ка кадәр арта. Әлеге чорда кече сәнәгый һәм коммуналь энергетика объектлары реконструкцияләнә, түбән вольтлы шәһәр челтәрләре үсеш кичерә. Махсуслаштырылган җитештерү пр-тиеләре — Казанда трансформаторларны ремонтлау базасы (1948) һәм «Татэнергоремонт» з-ды (1960) төзелә. 1957 дә Урыссу һәм Казан энергетика төйнәлешләре бердәм диспетчерлык хезмәте булган Татарстан ХХСның энергетика сәнәгате идарәсенә берләштерелә. Э. э. үсешенә карамастан, пр-тиеләр һәм халык электр энергиясен куллану бик тиз арткан шартларда 1950 еллар ахырына респ-када аңа кытлык саклана. Энергетика объектларын кору өчен «Татэлектромонтаж» (1957), «*Татэнергострой*» (1963), «*Камгэсэнергострой*» (1964), «*Камэнергострой*» (1969) оешмалары төзелә. 1960 елларда *Зәй ГРЭСын* (ЗГРЭС, 1963), 1 нче *Түбән Кама җылылык электр үзәген* (ТҖЭҮ, 1967), 3 нче Казан ТЭЦын (1968), 1 нче һәм 2 нче КТЭЦларда югары экономияле яңа казаннарны һәм турбиналарны файдалануга тапшыру хисабына ТАССРда электр станцияләренең куәте 3 тапкырдан күбрәккә арта. Респ-ка тулысынча үз-үзен электр энергиясе б-н тәэмин итә, аның арткан өлешен СССР БЭСна җибәрә башлый. Респ-каның эре электр станцияләрен читтән китерелгән ташкүмердән мазутка һәм табигый газга күчерү башлана. 1963 тән, «Татэнерго» җитәкчелеге астына, эре дәүләт электр челтәреннән башка кече сәнәгый, коммуналь һәм а.х. электр челтәрләре һәм җайланмалары туплана. 1960–68 дә 35, 110, 220 *кВ* көчәнешле Зәй-Казан (Киндерле), ЗГРЭС–Түбән Кама, Казан (Киндерле)–Чабаксар (Казан энергетика төйнәлеше СССРның Европа өлеше БЭСна керә), Зәй–Бөгелмә ЭТЛләре, Чаллы, Алабуга, Менделеев,

Чистай, Нурлат, Мөслим, Яңа Чишмә, Аксубай, Сарман, Минзәлә, Базарлы Матак, Алексеев, Апас, Буа, Чүпрәле, Байлар Сабасы, Вятка Аланы, Лаеш, Балтач, Тәтеш, Кукмара, Мамадыш, Куйбышев һ.б. торак пунктларда подстанцияләр сафка баса. Барлык сәнәгать, транспорт, а.х. һәм коммуналь-көнкүреш пр-тиеләрен һәм оешмаларын эре подстанцияләргә тоташтыру, нәтиҗәсез вак электр станцияләрен бетерү башлана (Чаллыда — 20, Чистайда 22 энергия җайланмасы эштән туктый). 1970 кә колхозлар — 96%, совхозлар — 98%, торак пунктлар 82% ка электрлаштырыла.

1972 дә ЗГРЭСны киңәйтү төгәлләнә, ул Европадагы иң эре җылылык электр станциясенә әверелә. КамАЗ ТЭЦы (1971, хәзер *Чаллы җылылык электр үзәге*), *Түбән Кама ГЭСы* (1979, ТГЭС), 2 нче ТГЭЦ



Түбән Кама ГЭСының машина залы.

(1980) сафка баса. 1 нче һәм 2 нче КТЭЦларда искергән энергетика агрегатларын сүтү башлана. 1986–90 да Түбән Кама р-нында 6 мең *МВт* куәтле Татар АЭСы төзелеше бара. 220 һәм 500 *кВ* көчәнешле Зәй–Киндерле (1970), ЗГРЭС–ТГЭС, ЗГРЭС–Куйбышев (өлкә, 1972), Казан (Киндерле)–Чабаксар ГЭСы (1978), Түбән Кама–Завод (Чаллы) (1979), Завод–ЗГРЭС, Казан–Чабаксар–Горький–Кострома–Мәскәү (икесе дә — 1980) ЭТЛләре һ.б. файдалануга тапшырыла. 1990 еллар башына Татарстанның энергетика системасы СССРдагы иң эре 7 система исәбенә керә, электр станцияләре гомуми куәтенең һәм электр энергиясе җитештерүнең макс. күрсәткечләренә ирешелә.

1980 елларның 2 нче яртысыннан Э.э. үсешендә төп игътибар гамәлдәге куәтләрне файдалануда нәтиҗәлелекне яхшыртуга, ягулык сарыф итүне, электр энергиясен тапшыруда югалтуларны азайтуга юнәлтелә. 1990 елларда сәнәгый җитештерү күләмнәре кимү, ш.у. 1 нче һәм 2 нче КТЭЦларда, УГРЭСта, ЗГРЭСта искергән җиһазларны сүтү нәтиҗәсендә электр энергиясен эшләп чыгару кыскара. 1990 елларның 1 нче яртысында Э.э. пр-тиеләре респ-каның хакимият органнары карамагына күчә. Энергия б-н тәэмин итүнең техник халәтен, куркынычсызлыгын, Э.э. куәтләрен нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту өчен ТР Энергетика күзәтчелеге дәүләт инспекциясе һәм Респ-ка энергия саклаучы технологияләр үзәге оештырыла (1997).

2000 еллар башыннан тармакны институциональ үзгәртеп кору барышында «Татэнерго» АҖ эшчәнлек төрләре буенча бернечә пр-тиегә бүленә һәм яшәүдән туктый (2011). Респ-када энергетика комплексы (кластер) формалаша. Электр энергиясен «Генерацияләүче компания» (ТГЭС, ЗГРЭС, 1 нче һәм 2 нче КТЭЦ, Чаллы ТЭЦы), «Урыссу ГРЭСы ТГК», «ТГК-16» (1 нче ТТЭЦ, 3 нче КТЭЦ) акц. җәмгыятьләре, «Түбән Кама ТЭЦы» ҖЧҖ (2 нче ТТЭЦ) җитештерә. 2014 тә респ-каның барлык электр станцияләренең куәте — 7,3 млн. *кВт*, электр энергиясе җитештерү 22,3 *кВт·сәг.* тәшкил итә. Электр энергиясен тапшыручы, электр челтәрләрен файдаланучы һәм аларга хезмәт күрсәтүче төп компания — «Челтәрле компания» АҖ, ул Әлмәт, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Казан, Чаллы, Түбән Кама, Идел буе, Чистай электр челтәрләрен үз эченә ала. 2014 тә ТРда ЭТЛләрнең гомуми озынлыгы: ачык линияләр — 59,5 мең *км* (ш.и. 35–500 *кВ* көчәнешлеләр — 10,2 мең *км*, 0,4–6 (10) *кВ* көчәнешлеләр — 42,4 мең *км*), кабельле линияләр — 9,1 мең *км* (35–220 *кВ* көчәнешлеләр — 101,5 *км*, 0,4–6 (10) *кВ* көчәнешлеләр — 9 мең *км*) тәшкил итә; 35–500 *кВ* көчәнешле подстанцияләр — 372, 0,4–6 (10) *кВ* көчәнешле трансформатор пунктлары — 18305. ТР терр-ясендә электр энергиясе б-н гарантияле тәэмин итүче оешма — «Татэнергосбыт» АҖ, ул 30 меңнән артык юридик затка һәм 700 меңнән артык физик затка хезмәт күрсәтә.

ТРда кирәкле стандартлашкан электр-техник җиһазлар, материаллар җитештерүче, сервис хезмәте күрсәтүче пр-тиеләр булдырыла. «ИНВЭНТ» компанияләр төркеме оештырыла, аның составында Казанда комплектлы бүлү җайланмалары, ЭТЛ терәк-баганалары, күбек полиуретан изоляцияле торбалар, кабельләр, трансформаторлар, Зәйдә блоклы комплектлы трансформатор подстанцияләре, металл конструкцияләр һәм металл эшләнмәләр, сэндвич-панельләр, Урыссуда комплектлы трансформатор подстанцияләре һәм калкан җиһазлар җитештерүче заводлар эшли.

Респ-када Э.э. үсешенең төп юнәлешләре — җылылык электр станцияләрен пар энергиясе турбиналарына алмашка нәтиҗәлерәк пар-газ турбиналары б-н яңартып җиһазландыру (әлеге турбиналар 1 нче ТТЭЦта һәм 2 нче КТЭЦта урнаштырыла), электр челтәренең тиз арада йөкләнеш артуга сәләтен (инновацион җиһазлар кулланып, Алабуга 500 *кВ*, Үзәк 220 *кВ* (Казан), Чистай 220 *кВ*



«Чистай-220» подстанциясе.

подстанцияләрен, 220 *кВ* көчәнешле Котлы Бөкәш-Үзәк ЭТЛн төзү, гамәлдәге Киндерле 500 *кВ*, Котлы Бөкәш 220 *кВ* подстанцияләрен реконструкцияләү), куәтнең агылыш реверсын тәэмин итү; кулланучыларны электр энергиясен куллану күләмен исәпкә алу һәм көйләү приборлары б-н җиһазлау. 2015 тә «Түбән Кама ТЭЦы» ҖЧҖнең станциясен модернизацияләү төгәлләнә, аның куәте 350 *МВт* ка кадәр арттырыла. Э.э. объектларын техник проектлау мәсьәләләрен Бөтенроссия энергетика сәнәгате фәнни тикшеренү-җитештерү ин-тының (ВНИПИ энергопром) Идел буе ф-лы, «КЭР-холдинг» ҖЧҖ, «Энергопрогресс» инженерлык үзәге һ.б. хәл итә. Э.э. өчен кадрларны ТРда Казан энергетика ун-ты һәм Казан энергетика техникумы әзерли.

Чыг.: История энергетики Татарстана (1920–2000 гг.): Док. и материалы. К., 2001.

*Әд.:* Развитие энергетики Татарской АССР. К., 1961; Мы и время: Очерки из истории энергетической системы Татарстана. Чебоксары, 2002; М и н н и х а н о в Р.Н. Энергетика Татарстана: динамичное развитие, новые достижения // Энергополис. 2008. № 1.

*С.Г.Белов, М.В.Сәлимгәрәев.*

**ЭЛЕ́КТРЛАШТЫРУ**, җитештерүгә һәм көнкүрешкә электр энергиясен киң куллануны кертү. Хәзерге Татарстан терр-ясендә Э. 1895 елда Казанда «Газ һәм электр» АҖгә караган (баштагы егәрлеге 120 ат көче, 1917 дә — 1900 ат көче) беренче шәһәр электр станциясен файдалануга тапшырудан башлана. Ул хөкүмәт учреждениеләрен, почта, телеграф, театр, дворяннар һәм офицерлар җыеннары биналарын, кайбер уку йортларын, Щеткин номерларын, Юшков һәм Кекин йортларын һ.б., Зур Проломный (Бауман), Воскресенский (Кремль), Грузинский (Карл Маркс), Московский, Покровский һәм Казан үзәгендәге кайбер башка урамнарны (1910 га урамнарны 106 фонарь яктырта), ш.у. (1898 дән) — Үзәк, Грузинский һәм Проломный урамнары буйлап уздырылган 3 трамвай линиясен (1910 га — 5 линия) электр б-н тәэмин итә. Бер үк вакытта Казан губернасындагы кайбер өязләрне (1914 кә өяз электр станцияләренең гомуми егәрлеге 400 *кВт* тан артык тәшкил итә), эре сәнәгать пр-тиеләрен (бертуган Крестовниковлар, Алафузовлар, «Поляр» һ.б.; иң зур пр-тиенең электр энергиясен куллану күләме бер елга 300 *кВт·сәг.*тән артмый) Э. башлана. 1920 нең июнендә Казан шәһәр ХХС Дәүләт корылмалары ком-тының гамәлдән чыгарылган электромеханика бүлекчәсе базасында ТАССР ХХС ның электротехник сәнәгать бүлеге оештырыла, ул Э., электр энергиясен бүлү, электр сәнәгате пр-тиеләре эшен җайга салу б-н шөгыльләнә. 1920 нең 22 декабрендә Россияне Э. дәүләт планы (*ГОЭЛРО* планы) раслана, ул Э. базасында 10 — 15 ел эчендә халык хуҗалыгын нигездән үзгәртеп кору бурычын куя. ГОЭЛРО планы буенча Э.ны терр-яләр үсешенә туры китереп гамәлгә ашыру күздә тотыла. 1921 нең гыйнварында Татарстанны Э. буенча совет төзелә. ГОЭЛРО планын раслаганнан соң, халык хуҗалыгы хезмәткәрләренең 1 нче Бөтентатар съезды ТАССРны

Э. планын эшләү турында резолюция кабул итә. Планны гамәлгә ашыру барышында 20 электр станциясе, ш.и. Казанда ТЭЦ-1 һәм ТЭЦ-2, Бөгелмә, Алабуга, Тәтеш, Чистай шәһәрләрендә, Кама Тамагы, Кукмара, Норлат авылларында ТЭЦлар сафка баса. Параллель рәвештә респ-каның транспорт системасын Э. алып барыла. ГОЭЛРО планы Казан энергетика төйнәлешен булдыруга, шәһәр, өлешчә авыл кулланучыларын (нигездә шәһәр яны колхозларында) үзәкләштерелгән электр энергиясе б-н тәэмин итүгә нигез сала. Яңа икътисади сәясәт (нэп) чорында «Кызыл таң» («Красная заря», 1923), ТАССРның 3 еллыгы исем. электр станцияләрен гамәлгә кертү б-н Казанда дәүләт учреждениеләрен, сәнәгать пр-тиеләрен, торак йортларны үзәкләштерелгән Э. башлана. 1931 нең 25 июнендә «Энергоцентр» дәүләт бөтенсоюз берләшмәсенең «Татэнерго» оешмасын — Татарстан дәүләт электр станцияләре район идарәсен төзү турындагы фәрманына кул куела.1933 нең гыйнварында Казан ТЭЦ-1 (КазГРЭС) сафка басу һәм аз экономияле электр энергиясе җайланмалары бетерелү б-н Казанның барлык электр энергиясен кулланучылары үзәктән тәэмин ителә башлый. Бер үк вакытта Казан шәһәре янындагы посёлокларны (Зеленодольск, Васильево) һәм колхозларны Э.га керешелә. Бөек Ватан сугышы елларында торак пунктларны, шәһәр һәм авыл пр-тиеләрен Э. процессы туктала, шәһәр халкына энергия җибәрү һәр кешегә бер айга 5 *кВт·сәг.* кә кадәр чикләнә. Дәүләт учреждениеләре, уку йортлары, хастаханәләр һәм госпитальләр, театрлар һәм кинотеатрлар, кибетләр өчен дә электр энергиясен куллануда катгый нормалар кертелә. Э. буенча эшләрне җайга салу өчен 1942 дә Дәүләт оборона ком-ты карары б-н Казан энергетика комб-ты «Казэнерго» район энергетика идарәсе итеп үзгәртелә. ТЭЦ-2 дә (1942) 2 нче турбогенератор, ТЭЦ-1 дә (1943) 3 нче турбогенератор җибәрелү б-н респ-када электр энергиясен куллану күләме сизелерлек арта. Яңа куәтләр булдыру процессына эвакуацияләнгән энергетика галимнәре Г.М.Кржижановский, К.И.Шефнер, Л.К.Рамзин, Л.М.Мелентьев, М.А.Стырикович һ.б. зур өлеш кертә. 1943 тә, Шөгер авылы тирәсендә нефть ятмалары ачылу б-н, нефть промыселларын Э. башлана. Баштарак дизель-насос җайланмалары, энергопоездлар, аннары Урыссу ГРЭСы (хәзер Ютазы р-нында) электр энергиясе кулланыла.

1950 еллар башына кадәр колхозлар һәм авылларны Э. нигездә җирле ресурсларны файдалану хисабына гамәлгә ашырыла: 1952 дә Ык елгасында Яңа Мәлкән ГЭСы, аннан соңгы елларда — Зөя елгасында Дәвеш һәм Кыят ГЭСлары (һәркайсы 270 шәр *кВт*) һ.б. сафка баса. 1960 та җирле 1840 электр станциясе эшләп килә. Әмма елгаларның аз сулылыгы һәм еш кына плотиналарны һ.б. корылмаларны агызып алып китүче көчле ташулар аркасында күп кенә колхоз ГЭСлары электр б-н тотрыклы тәэмин итүне оештыра алмыйлар. Урыннардагы вак җылылык электр энергиясе җайланмалары авылда яшәүчеләрнең минималь ихтыяҗларын тәэмин итә. 1951–55 тә 123 колхоз электрләштырыла (план буенча — 177); авылныкы булмаган электр станцияләренә 850 колхоз (план буенча — 1910) тоташтырыла. 1953 нең августында КПСС ҮК һәм СССР МСның «Колхозларны электрлаштыру буенча эшләрне дәүләт энергосистемаларына, сәнәгать һәм коммуналь электр станцияләренә кушу юлы белән башкару турында» карары кабул ителгәннән соң, кабат оештырылган «Татсельэлектро» идарәсенә Татарстан районнарын Э. буенча киң колачлы эшләр йөкләнә. 1956 да Биектау р-ны Чыпчык авылында 35 *кВт* көчәнешле 1 нче линия һәм авыл хуҗалыгы карамагындагы подстанция кулланышка кертелә. 1957 дә Идел ГЭСы төзелеп бетү һәм 1963 тә Зәй ГРЭСының 1 нче энергоблогы җибәрелү б-н (1972 дә 2400 *мВт*) авыл торак пунктларын Э. җәелдерелә. Бер үк вакытта экономияле булмаган кечкенә авыл һәм шәһәр электр станцияләрен бетерү һәм индивидуаль кулланучыларны үзәкләшкән электр энергиясе б-н тәэмин итүгә күчерү бара. Кама аръягы энергетика узелын СССРның Бердәм энергетика системасына тоташтырганнан соң, шәһәр һәм авыл торак пунктларын, респ-каның сәнәгать һәм а.х. пр-тиеләрен Э. үсешендә сыйфат ягыннан сикереш күзәтелә (1958). Казан энергетика төйнәлешен Кама аръягы б-н тоташтырган электр тапшыру линиясе (ЭТЛ)-220 (1963), Зәй–Киндерле — ЭТЛ-500 (1967), Казан–Чабаксар–Горький–Кострома–Мәскәү — ЭТЛ-500 (1978) һ.б. файдалануга кертелә. 1971 нең 1 гыйнварына 588 колхоз, 204 совхоз, 3350 торак пункт (3456 дан) 375700 авыл йорты (377300 дән) электрлаштырыла. 1970 еллар башында Татарстанда Э. нигездә төгәлләнә.

*Әд.:* к. *Электр энергетикасы* мәкаләсе.

**ЭЛЕКТРОАКУ́СТИК КАЙТАВА́З** (полярлаштыру кайтавазы), пьезоэлектрикларда аларга радио ешлыгындагы (РЕ) һәм үтә югары ешлыктагы (ҮЮЕ) алмаш электр кыры импульслары б-н тәэсир итү нәтиҗәсендә электроакустик тирбәнешләрнең когерентлыгы торгызылуы. Каты җисемнәрдә электр кыры аша акустик дулкыннарны генерацияләгән сызыкча һәм нәсызыкча механизмнарның үзара ярашуы, таралуы, үзгәрүе һәм сүнүе моның шартлары булып тора. Э.к. онта һәм поликристаллар рәвешендә РЕ-диапазонда 1970 елда бер үк вакытта СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында (А.Р.*Кессель*, И.А.*Сафин*), СССР ФАнең Ленинград физика-техника ин-тында (Н.Н.Крайник, С.Н.Попов) ачыла. ҮЮЕ-диапазонда монокристаллардагы йөгерек гипертавышлы дулкыннар режимында Э.к. иң элек 1971 елда СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында күзәтелә; Э.к.ның дәвамлы хәтере ачыклана (У.Х.Копвиллем, Б.П.Смоляков, Р.Ш.Шәрипов). Гипертавыш импульсының монокристалл үрнәк аша узуы вакытына кабатлы мизгелләрдәге дискрет Э.к. хасил булуы; тимер группалары элементларының ионнары б-н активлаштырылган кристалларда Э.к. сигналлары көчәюе ачыклана; пыялада Э.к. үзлекләре тикшерелә (Б.П.Смоляков, Е.И.Штырков, Б.З.Малкин, Е.П.Хаймович). СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында РЕ-диапазонда пьезоэлектриклар онтасында аномаль дәвамлы хәтер булуы беленә һәм аңлатыла (Я.Я.Әсәдуллин, В.М.Берёзов, В.Д.Корепанов, В.С.Романов); сегнетоэлектрик фаза күчешләре темп-ралары өлкәсендәге монокристалларында Э.к. табыла; таррак темп-ра өлкәсендә акустик субгармоникалар генерациясе билгеләнә (В.И.Башков, В.М.Берёзов, В.Д.Корепанов, В.С.Романов, Н.К.Соловаров). Э.к. каты җисемнәрнең микроскопик характеристикаларын тикшерүдә перспектив алым булып тора.

*Әд.:* С м о л я к о в Б.П., Х а й м о в и ч Е.П. Динамические процессы в диэлектрических стёклах при низких температурах // Успехи физ.наук. 1982. Т. 136; К о п в и л л е м У.Х., П р а н ц С.В. Поляризационное эхо. М., 1985; Поляризационное эхо и его применение. М., 1992.

*Н.К.Соловаров.*

**ЭЛЕКТРОАНАЛИ́ТИК ХИ́МИЯ**, аналитик химиянең бүлеге, электрод — эретмә чигендә электр корылмаларын күчерү процессларыннан файдаланып эретмәләрдәге матдәләрне ачыкларга һәм аларның эретмәләрдәге концентрациясен билгеләргә мөмкинлек бирүче алымнарны берләштерә. Казан галимнәре Э.х. үсешенә зур өлеш кертә. Иң элек полярография өлкәсендә эшләр башкарыла: эретмәләрдәге металл комплекслары тотрыклылыгын бәяләү өчен потенциометрия кулланыла (В.Ф.Торопова). Полярография һәм вольтамперометрия принциплары амперометрик титрлау алымнарын файдалану аркасында үсеш ала (А.А.Поппель, А.И.Костромин һ.б.). Полярография һәм вольтамперометриянең башка юнәлешләре дә: азометин кушылмалары (Ю.П.Китаев), кино-фото сәнәгате өчен ачыгайтучы матдәләр һ.б. кушылмалар (В.М.Гороховский), аминлы һәм күкертле кушылмалар (В.И.Гороховская), сусыз мохитларда органик матдәләр (Ю.М.Каргин) полярографияләре; терекөмеш электродында водородның каталитик бүленүе, электр тупланышын файдалану (В.Ф.Торопова), осциллополярография, полярография һәм вольтамперометрия кулланылган катнаш алымнар (Г.К.Будников), экстракцион вольтамперометрия (Н.А.Улахович), кулонометрия һәм кулонометрик титрлау (А.И.Костромин), органик кушылмалар кулонометриясе (А.Ф.Абдуллин) алгарыш процессы кичерәләр. Казан ун-тының Россиядә бердәнбер булган кулонометрик органик анализ лаб-ясендә биоматрицалардагы антиоксидантлар, биологиядә һәм медицинада зур әһәмияткә ия фарм. һ.б. препаратлар тикшерелә. Матдәләрне вольтамперометрик билгеләүнең сизгерлеге һәм сайлаучанлыгы дәрәҗәсен күтәрү өчен электрод өслеге модификацияләнгән күмер пасталы электродлар, каталитик кайтавазлы химик яктан модификацияләнгән электродлар кулланыла. Биологик ак-

тив кушылмаларның үтә түбән концентрацияләрен билгеләргә мөмкинлек бирүче *биосенсорлар* һәм биосенсорлы җайланмалар булдырыла. Биосенсорлар кайтавазының селективлыгын тәэмин итү максаты б-н электродларны ДНК, аларның ш.и. синтетик фрагментлары б-н иммобилизацияләнгән ток үткәргеч полимер элпәләр б-н каплануга нигезләнгән модификацияләгән технологияләр эшләнә. Шул ук мәсьәлә сигналы амперометрик ысул б-н теркәлгән иммунохимик реакцияләр принцибы нигезендә дә хәл ителә (Г.К.Будников, Г.А.Евтюгин, Э.П.Медянцева, С.С.Бабкина һ.б.). Казан ун-тында үткәрелгән фундаменталь тикшеренүләр электрод процесслары турында потенциалның омлы югалтулары компенсацияләнеп, сыйдырышлы токлар һәм башка факторлар бастырылып, мәгълүмат бирүче, шуның б-н вольтамперометрик алымның ышанычлылыгын арттыручы вольтамперографлар булдыру мөмкинлеге бирә (Р.Ш.Нигъмәтуллин, М.Р.Вяселев).

*Әд.:* Будников Г.К. Развитие электрохимических методов в Казани // Журн.аналит.химии. 2000. Т. 55, № 3; Будников Г.К. Аналитическая химия в Казанском университете: фрагменты истории. К., 2003.

*Г.К.Будников.*

**ЭЛЕКТРОКАРДИОГРА́ФИЯ**, к. *Физиология.*

**ЭЛЕКТРО́Н ПАРАМАГНЕ́ТИК РЕЗОНА́НС** (ЭПР), тышкы магнит кырында булган, парамагнетик үзәкләрне үз эченә алган матдә тарафыннан электромагнетик кыр энергиясенең резонанслы йотылуы. ЭПР күренешендә электрон спиннары мөһим роль уйнаганлыктан, аның башка исеме дә бар — спин резонансы. Атомнар, молекулалар, ионнар, эчке һәм тышкы тутырылмаган электрон сүрүле ирекле радикаллар, буяу үзәкләре, радиацион һәм фотоиндукцияләнгән үзәкләр, ярымүткәргечләрдәге донорлар һәм акцепторлар, үткәрүчәнлек электроннары парамагнетик үзәкләр була ала. Парамагнетик үзәкләр нульдән аерылып торучы магнит моментына ия, аңа исә нульдән аерылып торучы электроннар хәрәкәте микъдары моменты шарт булып тора.

ЭПР күренешен 1944 елда Казан ун-тында Е.К.*Завойский* ача. ЭПР алымы үсешенә Россия, ш.и. Казан галимнәре (к. *Казан радиоспектроскопия фәнни мәктәбе*) — Л.К.Әминов, Л.А.Блюменфельд, Н.С.Гарифҗанов, М.М.Зарипов, Б.И.Кочелаев, Я.С.Лебедев, К.М.Салихов. А.Г.Семёнов, Ю.Д.Цветков, Л.Я.Шекун, ш.у. чит ил галимнәре — А.Абрагам, Б.Блини, Д.Инграм, Дж.Фэхер, А.Швайгер һ.б. зур өлеш кертәләр.

**ЭПР күренешенең классик интерпретациясе** (1 нче рәс.). ЭПР бер үк вакытта $H_1$ радиоешлыклы магнит кыры үрнәгенә тәэсир итү шарты б-н $H_0$ даими магнит кырында күзәтелә. Классик күзаллауларга караганда, $H_0$ даими магнит кырының $\mu$ магнит моменты б-н тәэсир итешүе $H_0$ тирәли момент прецессиясе б-н нәтиҗәләнә. $H_0$ гә перпендикуляр булган $\upsilon$ ешлыклы $H_1$ радиоешлыклы магнит кыры прецессия почмагы үзгәрүенә сәбәпче була, ягъни, магнит моменты проек-




1 нче рәсем. ЭПР күренешенең классик интерпретациясе.

циясенең зурлыгын $H_0$ кыры юнәлешенә үзгәртә, шул ук вакытта $H_1$ радиоешлыклы кыр энергиясе йотыла.

**ЭПР күренешенең квант-механик интерпретациясе** (2 нче рәс.). $H_0$ даими магнит кырының парамагнетик кисәкчәсе энергиясе кимәлләре таркалу нәтиҗәсендә хасил булган магнетик (Зееман) асдәрәҗәләр арасындагы $\Delta E$ энергияләре аермасы квантның $h\upsilon$ (биредә h — Планк даимисе) энергиясенә тигез булу очрагы бар. Бу шарт үтәлгәндә $H_1$ радиоешлыклы кырының электромагнетик кванты йотылу күренеше барлыкка килә. Резонансның шарты $h\upsilon=\Delta E=g_e\beta H_0$ рәвешендә языла. Әгәр парамагнетик кисәкчәнең магнит моментына бары тик S = 1/2 электрон спины шарт булып торса, ул вакытта $g_e$=2,0023 — ирекле электрон өчен спектроскопик таркалу факторы, $\beta$ — Бор магнетоны, $M_s$ — $\pm1/2$ дәрәҗәсен кабул иткән спин




2 нче рәсем. ЭПР күренешенең квант-механик интерпретациясе.

проекцияләре. Тышкы магнит кырында $H_0$ $-g_e\beta H_0/2$ һәм $+g_e\beta H_0/2$ электрон спинының ике проекциясенә туры килгән ике энергия дәрәҗәсенә (магнит асдәрәҗәләр) ия. Араларындагы энергия аермасы — $g_e\beta H_0$. $H_1$ радиоешлыклы кыр тәэсире нәтиҗәсендә электроннар бер дәрәҗәдән икенчесенә күчә, бер үк вакытта спин ориентациясе дә үзгәрә. Электромагнетик энергия түбән дәрәҗәдән югарысына күчкәндә йотыла, кире күчкәндә таркала. Бу процессларның ихтималлыгы бердәй, әмма тигезләнеш шартларында түбән дәрәҗәдәге электроннар микъдары югарысына караганда артык була һәм нәтиҗәдә $H_1$ радиоешлыклы кыр энергиясе йотыла.

Әгәр S>1/2 икән, ул вакытта төрле $|M_s|$ лы энергия дәрәҗәләре $H_0$=0 шарты үтәлгәндә таркала. Шул вакыт ЭПР спектрында бернычә йотылу сызыклары ягъни ЭПР спектрының нечкә структурасы күзәтелә. Электроннар парамагнетик атом төшенең магнит моменты яки иң якын тирәдәге төшләрнең магнит моментлары б-н үзара тәэсир итешү нәтиҗәсендә ЭПР спектрларының үтә нечкә структурасы хасил була. Парамагнетик кисәкчә электроннарының иң якын тирәдәге төшләрнең магнит моментлары б-н үзара тәэсир итешү очрагында ЭПР супер үтә нечкә структура дәрәҗәсенә җитеп таркала. ЭПР спектрының үтә нечкә һәм супер үтә нечкә структураларын тикшерү парамагнетик үзәк локализациясенең ачыкларга мөмкинлек бирә. Гадәттә, кисәкчәләр парамагнетизмы бернычә электронның орбиталь һәм спин моментлары гомуми өлеше шартына бәйле; кристалларда бу электроннарга әйләнә-тирәдәге ионнарның (лигандлар) көчле электр кырлары тәэсир итә. Шул сәбәпле ЭПР спектрларын тасвирлау — катлаулы бурыч. Спектрларны хисаплау өчен 1951 дә А.Абрагам (Франция) б-н Х.Прайс (АКШ) тәкъдим иткән спинлы гамильтониан алымын файдаланалар.

**Эксперименталь ЭПР алымнары**. ЭПР спектрларын үлчәү максаты б-н үрнәктә йотылган $H_1$ радиоешлыклы егәрлекнең үзгәреше теркәлә. Мондый үлчәү өчен $\nu$ даими ешлыгы һәм $H_0$ магнит кыры зурлыгының әкрен үзгәрүе зарур шартлар булып тора. Тикшеренүләр вакытында өзлексез хәрәкәтле (стационар ЭПР) һәм импульслы спектрометлар кулланыла. Берүлчәмле һәм күпүлчәмле вариантларда берле һәм күплекле магнетик резонанс алымнары файдаланыла. Киң кулланылучы импульслы ЭПР һәм югары магнит кырларындагы ЭПР методикалары фәзаи-электрон структура, ш.у. төрле процесслар динамикасы хакында уникаль мәгълүматлар бирә. Кыска гомерле парамагнетик халәтләр (мәс., фотосинтезның беренче стадиясендәге бер-берсеннән аерылган корылмалар, триплет халәтендәге фотоярсулы молекулалар һ.б.) вакытлы хәл итүле ЭПР спектроскопиясе ярдәмендә тикшерелә. Үтә нечкә структураларны спектроскопияләү алымы электрон спин кайтавазы уратмасының берле яки икеле модуляция техникасын, куш электрон-төш резонансын һәм куш электрон-электрон резонансын үз эченә ала.

**ЭПРны куллану.** ЭПР алымы һәм аның хәзерге заман модификацияләре парамагнетик үзәкләрнең табигатен һәм структурасын, электрон тыгызлыкның концентрациясен ($см^3$га 108–1020 кисәкчә диапазонында), локализациясен һәм таралышын, иң якын тирәлеге б-н бәйләнеш характерын, релаксация сыйфатламаларын, парамагнетик үзәкләр арасындагы араны ачыклауга юл ача. Электроннар арасындагы араны үлчәү алымнары полимерлар, наноматериаллар һәм мицелләр эретмәләр биомолекулалары структурасының шифрларын ачу өчен кулланыла.

ЭПР матдә структурасын гына түгел, молекуляр динамиканы, фаза күчешләрен, хи-

мик реакцияләрнең механизмнарын тикшерү өчен кирәкле иң информатив эксперименталь тикшерү алымнарыннан берсе. Аны үзенең парамагнетик үзәге булган объектны яисә системага зонд буларак кертелгән парамагнетик үзәкләрне тикшергәндә файдаланалар, физика, химия, геол., биол., мед., материаллар белемендә кулланалар. Е.К.Завойский эшләгән Казан ун-ты лаб-ясендә аның исемендәге музей оештырыла. РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында «Applied Magnetic Resonance» һәм «EPR News Letter@» исемендә ике халыкара фәнни журнал нәшер ителә. Ш.у.к.: *Ирекле радикаллардагы ЭПР*.

*Әд.:* Завойский Е.К. Парамагнитная релаксация в жидких растворах при перпендикулярных полях // Журн.эксперим. и теорет.физики. 1945. Т. 15, № 7; Альтшулер С.А., Козырев Б.М. Электронный парамагнитный резонанс. М., 1961; Керрингтон А., Мак-Лечлан Э. Магнитный резонанс и его применение в химии. М., 1970; Абрагам А., Блини Б. Электронный парамагнитный резонанс переходных ионов: В 2 т. М., 1972–73; Болтон Дж., Вертц Дж. Теория и практические приложения метода ЭПР. М., 1975; Салихов К.М., Семёнов А.Г., Цветков Ю.Д. Электронное спиновое эхо и его применение. Новосиб., 1976; The Treasures of Eureca. V.1. Electron paramagnetic resonance. Wellington, New Zealand, 2009. *Н.И.Силкин, Р.Г.Усманов.*

**ЭЛЕКТРООРГА́НИК ХИ́МИЯ**, эретмәләрдәге органик матдәләрнең электр тогы тәэсирендә булган әверелешләрен тикшерә. Россиядә органик электрохимия өлкәсендәге беренче эш буларак валерьян к-тасы эретмәсенең электролизы санала (А.М.Бутлеров). 20 йөзнең 2 нче яртысында Казанда органик матдәләрнең әверелешләрен тикшерү башланып китә. Тәҗрибәләр вакытында полярография (Ю.П.Китаев), полярография һәм вольтамперометрия (Ю.М.Каргин), төрле кристаллографик характеристикалы электрод-монокристалл реакцияләре (В.Н.Никулин) алымнары кулланыла. Э.х.нең аналитик аспектлары да эшләнә (В.М.Гороховский, В.И.Гороховская, Г.К.Будников). Э.х.нең тикшеренү объектлары буларак электрохимик активлыкка ия нуклеофил һәм электрофил төркемнәр — альдегидлар, кетоннар, нитрокушылмалар катнашкан органик кушылмалар хезмәт итә. Электрод реакцияләрнең аерым стадияләре төрле тирәлекләрдә нинди роль уйнаулары ачыклана (химик реакцияләр, элиминлаштыру, протонлаштыру стадияләре, каталитик процесслар, электрон күчергечләр кулланылган медиатор процесслар). ЭПР алымын куллану радикаль табигатьле кисәкчәләрнең арадаш формаларын табарга мөмкинлек бирә (Ә.В.Ильясов, М.К.Кадыйров). Нитрлау, фосфорорганик кушылмалар (ФОК), югары олефиннарны хлорлау процесслары буенча нәтиҗәләр алына. РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында ФОКны синтезлауның эффектив электрокаталитик алымнары эшләнә, органик һәм металлорганик кушылмалар тәэсире астында элементлы фосфорның электрохимик активациясе һәм трансформациясе процессларын тикшерү юнәлеше үсеш ала. ФОКның мөһим класслары булган триалкил-, тирарил-, триамид- һәм диалкилфосфатларны, өченчел фосфиннарны, ак фосфордан фосфон тозларын металл комплекслы катализ шартларында электросинтезлау өчен югары нәтиҗәле, энергия саклаучан һәм экологик яктан куркынычсыз технологияләрнең фәнни нигезләре булдырыла. Көчешле металлар катнашында электрокаталитик процесслар эшләнә, аларның закончалыклары һәм катализаторларның реакция мөмкинлеген билгеләүче факторлар ачыклана. P-E (E=C, O, N, Si) бәйләнешле төрледән-төрле кушылмаларны синтезлау, электрохимия алымнары б-н нәтиҗәләрәк реагентларны сайлауны прогнозлау алымнары, металл комплексы катализы шартларында ак фосфорның тетраэдры ачылу механизмын тикшерүгә яңа ысуллар тәкъдим ителә (Ю.Г.Будникова, Ю.М.Каргин, О.Г.Синяшин). ФОКны ак фосфордан чыгару буенча яңа югары нәтиҗәле экологик саф ысуллар эшләү буенча куйган хезмәтләре өчен Казан электрохимиклары халыкара медаль һәм дипломнарга, респ-ка конкурслары бүләкләренә, ТР Дәүләт бүләгенә (2007) лаек була. Бу өлкәдәге тикшеренүләр P-E (E=C,N,O,H, металл һ.б.) бәйләнешен формалаштыруның гадәти булмаган юлларын ача, спиртлар, аминнар, органогалогенидлар, олефиннар һәм башкаларга фосфор атомнарын кертүгә ишек ача, фосфиннар, нәорганик фосфор к-талары һәм аларның чыгарылмалары, фосфор к-тасының органик чыгарылмалары, функциональшкән фосфорорганик олигомерлар һәм полимерлар һ.б. кебек авыр табылышлы фофосфорорганик матдәләрне барлыкка китерүне җиңелләштерә (О.Г.Синяшин, Ю.Г.Будникова, Э.С.Батыева, Б.Е.Иванов). Молекуляр тану системаларын булдыру масскатында индолизиннарның электрохимик реакцияләре тикшерелә, каликс[4]ареннар һәм металл комплекслары, металл комплексларын п-сульфанато(тиа)каликс[4]аренар б-н электр көчешле бәйләү, ш.у. металл ионнарын бииндолизин гетероциклофаннар һәм аларның ациклик аналоглары б-н бәйләү нигезендә наноүлчәмле супрамолекуляр системаларының электрод реакциясе термодинамикасы өйрәнелә (хезмәткәрләре б-н берлектә В.В.Янилкин). Э.х. өлкәсендәге төп тикшеренү үзәкләре булып РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-ты, Казан ун-ты тора. *Ю.Г.Будникова, Г.К.Будников.*

**«ЭЛЕКТРОПРИБО́Р»**, электр техникасы һәм электроника җиһазларын проектлаучы, җитештерүче, модернизацияләүче, ремонтлаучы, аларга хезмәт күрсәтүче пр-тие; Россиядә авиация приборлары төзү тармагының күптәнге, әйдәп баручы пр-тиеләренең берсе. Эшләүчеләр саны — 1500 тирәсе кеше (2015). Тарихы 1916 елда Киевта нигезләнгән Үзәк аэронавигация станциясе авиаостаханәләреннән башлана. 1917 дә алар җирлегендә Мәскәү казна авиация үлчәү приборлары һәм инструментлары з-ды оештырыла (1918 дән 1 нче дәүләт үлчәү приборлары һәм инструментлары з-ды, 1933 дән җылылык үлчәү приборлары з-ды, 1937 дән 230 нчы з-д), 1941 нең көзендә Казанга эвакуацияләнә. 1967 дән Казан «Э.» з-ды. 1999 дан дәүләт унитар пр-тиесе, 2004 тән «Казан «Элекон» заводы» АҖ.

Бөек Ватан сугышы чорында завод сугыш самолетлары, танклар, корабльләр өчен тахо- һәм термометрия приборлары чыгара. Сугыштан соңгы елларда пр-тиенең җитештерү юнәлеше үзгәртелә, ул шактый киңәйтелә һәм модернизацияләнә. 20 йөзнең икенче яртысында СССРда беренче тапкыр МиГ-21 истребительләре, киләчәктә реактив истребительләрнең һәм бомбардировщикларның күп кенә башка модельләре өчен автопилотлар һәм идарә системаларын җитештерү үзләштерелә. Радиолокацион төзәүле «һава-һава» класслы һәм тепловизион төзәүле «һава-җир»



Авиация двигательләре өчен парлы үлчәү аппаратлары үрнәкләре.

класслы ракеталар өчен гироскопик стабилизаторлар, космик корабльләрнең автомат рәвештә тоташуы системалары өчен гиростабильләшкән платформалар (алар ярдәмендә орбитада 150 дән артык тоташтыру гамәлгә ашырыла) эшләү җайга салына. Автомат идарә итү, янгын сигнализациясе, температураны һәм двигатель әйләнешләрен тәртипкә салу авиацион системаларын җитештерү оештырыла. 1990–2000 елларда завод «Ансат» һәм Ми-172 вертолетлары өчен идарә системалары һәм башка эшләнмәләр, югары төгәллекле ракета комплекслары өчен гиростабильләшкән платформаларның яңа төрләрен, ш.у. сәнәгать приборлары, автомобиль компонентлары, халык куллануы товарларын җитештерүне үзләштерә.

Завод структурасына җыю, электромонтаж, механика, кою, эретеп ябыштыру, штамповкалау, гальваника, лак-буяу, инструментлар производстволары керә. Пр-тиедә сыйфат б-н идарә итү системасының халыкара ISO 9001–2001 стандартына туры килүе расланган.

Төп продукция — идарә итү, үлчәү, сигнал һәм көйләү приборлары һәм системалары Россиядә җитештерелгән барлык тип самолетларда һәм вертолётларда, авиация двигательләрендә файдаланыла. Шулай ук газ, химия сәнәгатьләре һәм энергетика җиһазлары өчен югары басымдагы газлы мохиттә температура үлчәү җайланмалары, йөк машиналары һәм җиңел машиналар өчен комплектлаучы детальләр, йозаклар, металл хуҗалык эшләнмәләре, сувенирлар җитештерелә. 2000 елларда завод берничә тапкыр «Рос-

сиянең иң яхшы экспортёры», «Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсларында җиңүче була.

«Э.» тарафыннан гомуми мәйданы 100 мең $м^2$ дан арткан 20 дән артык торак йорт, тулай торак, 10 мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре, поликлиника, хастаханә, ял базасы, балалар сәламәтләндерү лагеры һ.б. объектлар төзелә.

Пр-тиенең 250 дән артык хезмәткәре дәүләт бүләкләренә — орденнарга һәм медальләргә, 20 гә якын кеше мактаулы исемнәргә лаек була.

Завод директорлары: Н.А.Романов (1940–43), А.Н.Соколовский (1943–45), П.П.Волков (1945–46), Я.Н.Благой (1946–48), С.А.Губанов (1948–55), Ф.Ф.Павлович (1955–66), Ә.М.*Яушев* (1966–87), Г.В.Дивавин (1987–2007, 2007 дән — директорлар советы рәисе), П.А.Шацких (2007 дән).

*Әд.:* Дегтярев Г.Д. Сафариев М.С., Хлебников А.А. Аэрокосмический комплекс Казани. К., 2007.

*С.Г.Белов, Г.Я.Мәүлетова.*

**ЭЛЕКТРОХИ́МИЯ**, физик химиянең каты һәм сыек системаларның күләмчә һәм өслекчә үзлекләрен, ш.у. фазаара чикләрдә ионнар катнашындагы процесслар механизмын тикшерүче бүлеге. Электрохимик күренешләр заряд (электроннар) күчеше б-н бәйле һәм электр тогының йомык система аша узуы б-н тәгәлләнә. Электрохимия фәне Италия анатомы һәм физиологы Л.Гальванинның бака мускулларында тәҗрибә ясавыннан башлана (1771). Токның беренче химик чыганагы — «вольт баганасы» уйлап табыла (1779); саф хәлендә натрий, калий, барий, стронций, кальций, магний алына; электр аккумуляторы ясала, гальваник өслекләр процессы эшләнә, электролиз кануннары ачыла. Э. 20 йөздә аеруча зур алгарышка ирешә, бу электролитлар, адсорбция һәм икеле электр катламы теориясе, электрохимик термодинамика һәм кинетика үсеше б-н бәйле була. Электрохимик анализ алымы — полярографияне уйлап тапканы өчен чех галиме Я.Гейровский Нобель бүләгенә лаек була (1959). Гамәли Э.нең тармаклары булган гальванотехника, гальванопластика, электрохимик җитештерү, токның химик чыганаклары һ.б. техник эшләнмәләр шактый дәрәҗәдә үсеш ала. Казан галимнәре фундаменталь һәм гамәли Э. фәне үсешенә зур өлеш кертә. А.С.Савельевның гальваника һәм электр буенча хезмәтләре, Н.П.Слугиновның электролиз барышында электрохимик процессларны тикшерүе, А.М.Бутлеров тарафыннан углеводородлар синтезы өчен электрохимик алым кулланылуы, А.Е.Арбузовның гидразоннар һ.б. азометиннарның таутометриясен өйрәнү максатында полярографик алымнан файдалануы бу үсеш кысасында карала. Нәорганик кушылмаларның сыек утлы (эретелгән) хәлдәге Э.се (А.Я.Богородский), коллоид-электрохимик системаларны тикшерү (А.Ф.Герасимов), электроаналитик химия (А.М.Васильев) һәм сулы эремәләрдә комплекслар хасил булу мәсьәләләренә (В.Ф.Торопова) караган эшләр башкарыла. 1930 елларда Казан илдә Э. фәне үсеше үзәкләренең берсенә әверелә. Казан химия-технол. ин-тының физик һәм коллоид химия кафедрасында электрохимик лаб. булдырылып, аның базасында инженер-электрохимиклар әзерләү башлана, сәнәгый пр-тиеләр б-н тыгыз элемтә урнаштырыла. Г.С.Воздвиженский җитәкчелегендә гальванотехниканың актуаль мәсьәләләре эшләнә, галим металлар һәм эретмәләр электродекристаллизациясе фәнни юнәлешенә нигез сала; металл ионнары катнашында катод һәм анод процессларын, катодтан бүленмәләр һәм водород адсорбциясен тикшерү эшләре башкарыла (Г.П.Дезидерьев). С.М.Кочергин җитәкчелегендә металлар һәм эретмәләр өстенә йөгертелгән электрохимик капламаларның текстурасы һәм структурасы, электрод процессларына ультратавыш тәэсире өйрәнелә. Электрокатализ (В.И.Никулин), өслекчә актив матдәләрнең электрохимик адсорбциясе (Г.А.Добреньков), полимер электрохимик капламалар (Г.Я.Вяселева) өлкәләрендә эшләр башкарыла, газлы электр бушануларындагы реакцияләр тикшерелә (К.Н.Мочалов). Металлар һәм эретмәләрнең катодлы төпкә утыру һәм анодлы эрү электрод процессларында комплекслар хасил булуның һәм протоннар йогынтысының роле ачыклана (Н.В.Гудин, С.И.Березина). Полимер электролитларның сусыз эремәләре теориясен үстерүгә В.П.Барабанов шактый зур өлеш кертә. Р.С.Сәйфуллин яңа фәнни юнәлешкә — композицион электрохимик капламалар һәм материаллар булдыруга башлангыч бирә. Аның һәм шәкертләре (И.А.Габдуллин, И.Г.Хәбибуллин) тарафыннан эшләнгән яңа материаллар приборлар һәм машиналар төзү сәнәгатендә кулланыла. Э.нең гамәли өлкәсенә килгәндә, металлар һәм эретмәләрнең анодлы оксидлашу технологиясе һәм теориясенә (А.Ф.Богоявленский), металларда катодлы төпкә утыру процессларына, анод эшкәртелешенә һәм металлар пассивациясенә (Ф.Ф.Фәйзуллин һ.б.), электрохимик капламаларның формалашу һәм коррозияле җимерелү процессларын модельләштерүгә (И.Н.Андреев) багышланган хезмәтләр чыга. Функциональ гальванотехника технологияләрен камилләштерү, хромникель эретмәләргә карата мониторинг һәм локаль коррозиядән саклау, металл һәм эретмәләрне югары тизлекле селектив электр утырту технологияләрен эшләү (Р.Г.Кайдриков, Б.Л.Журавлёв, Я.В.Ившин) буенча тикшеренүләр алып барыла. Металл оксидлары нанокисәкчәләрен, күп фазалы металл-оксид һәм интерметаллик системаларны синтезлау (А.Ф.Дресвянников), өслекчә актив матдәләрне кушып комплекслы электролитлы металлар һәм эретмәләрне электр утырту (Н.Б.Березин) юнәлешендә эшләр башкарыла. Теоретик Э. өлкәсендә Э. фәненең бер төркем төп мәсьәләләрен хәл итүгә юл ачкан, электрод өслекнең кластер моделен, квант химиясе һәм квант-механик теориясе алымнарын файдалануга (М.С.Шапник, А.М.Кузнецов) нигезләнгән фәнни юнәлеш булдырыла. Электрод процесслары өчен компьютерлы квант-химик модельләштерү ысуллары эшләнә (Р.Р.Нәҗметдинов). Казан галимнәре тарафыннан гамәлгә ашырылган проектлар гальваник капламалар, төгәл металл күчермәләр, композицион материаллар ясау максатында, агынты сәнәгый суларны зарарсызландыру һ.б. эшчәнлек өлкәләрендә кулланыла. Э. буенча тикшеренүләр Казан технол. ун-тында, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, Казан ун-тында, Казан техник ун-тында алып барыла.

*Әд.:* Колотыркин Я.М., Петрий О.А. Достижения и задачи теоретической и прикладной электрохимии // Вестн.РАН. 1983. Т. 53, № 6; Дамаскин Б.Б., Петрий О.А., Цирлина Г.А. Электрохимия: Учеб. для вузов. М., 2001; Кузнецов А.М. Профессор Г.С.Воздвиженский: Жизнедеятельность, воспоминания, очерки и материалы. К., 2005.

*А.М.Кузнецов.*

**ЭЛЕМЕНТОРГА́НИК КУШЫЛМАЛА́Р**, үз эченә углерод-элемент (водород, углерод, күкерт, азот, кислород, галогеннар кебек элемент-органогеннардан тыш) химик бәйләнешен алучы органик кушылмалар. Биол. процессларда катнашучы кайбер органик фосфор кушылмаларыннан, ш.у. мышьяк һәм кобальтның аз сандагы кушылмаларыннан (мәс., $B_{12}$ витамины молекуласында булган кобальт-углерод бәйләнеше) тыш күпчелек элементларның органик чыгарылмалары табигатьтә юк. Билгеләнгән структуралы тәүге Э.к. (цинк, терекөмеш, бор, аккургаш, фосфор, мышьяк, кургаш, сөрмә, висмут, алюминий, кремнийның органик чыгарылмалары 19 йөзнең 1нче яртысында синтезлана. Эксперименталь һәм сәнәгый синтетик химия үсеше магний органик чыгарылмаларын ачу б-н бәйле (француз химиклары В.Гриньяр, П.Сабатье, Нобель бүләге, 1912). Сифилисны дәвалау өчен сальварсан препараты (мышьякорганик кушылма) булдырыла (немец табибе П.Эрлих, Нобель бүләге, 1908); машина ягулыгы антидетонаторы буларак тетраэтилкургаш тәкъдим ителә (Америка химигы Т.Мидгли, 1922). 20 йөз башында Казанда (А.Е.Арбузов) һәм Германиядә (немец химигы А.Михаэлис) *фосфорорганик кушылмалар* химиясе үсеш ала. Ферроценны («сэндвич структуралы» беренче металлорганик кушылма) ачу б-н Э.к.ны классик органик һәм нәорганик матдәләрдән аерып торган яңа полиэдрик структураларны һәм күпүзәкле күпэлектронлы бәйләнешләрне өйрәнүче яңа фәнни тармак — Э.к. химиясе формалаша. Мәскәү, Ленинград, Иркутск, Киев фәнни үзәкләрендә фосфор, кремний, тимер һ.б. металл органик кушылмаларның химиясе өлкәсендә тикшеренү эшләре башланып китә. А.Н.Несмеянов җитәкчелегендә дөньяда беренче буларак СССР ФАдә Элементорганик кушылмалар ин-ты оештырыла (Мәскәү, 1954). Э.к.ның хәзерге чор юнәлешләренең берсе — элементалкен б-н-алкиннарның (этилен һәм ацетиленның элементорганик аналоглары) элемент-углерод һәм элемент-элемент рәвешендәге кабатлы бәйләнешле молекулаларын барлыкка китерүе. Икеле һәм өчле бәйләнешле углерод-фосфор, икеле бәйләнешле фосфор, икеле һәм өчле бәйләнешле кремний-кремний молекула-

ларын стабильләштерү синтезы алымнары һәм принциплары эшләнә.

20 йөзнең 2 нче яртысында Татарстанда экспериментал һәм теоретик фосфорорганик (А.Е. һәм Б.А.Арбузов, А.Н.Пудовик), мышьякорганик (Г.Х.Камай) химия, кремнийның мономер һәм полимер чыгарылмалары (органосилоксаннар) өлкәсендә интенсив тикшеренүләр алып барыла; С.М.Киров исем. Ясалма каучук з-дында полисилоксаннарны сәнәгый җитештерү башлана. 1970–90 елларда яңа тип фосфоркремний һәм фосфораккургашорганик кушылмалар тикшерелә (Мәскәү һәм Иркутск галимнәре б-н берлектә Э.Ә.Ишмаева, Г.А.Кутырев, Р.Ә.Черкасов). Э.к.ның структурасы б-н үзлекләре арасындагы үзара бәйләнешне тикшерү аларны микъдар җәһәтендә бәяләү һәм химик үзлекләрен алдан әйтү мөмкинлеген бирә (В.И.Галкин, Р.Ә. һәм А.Р.Черкасовлар). Металлорганик химия өлкәсендә дә тикшеренү эшләре үсеш ала (О.Г.Синяшин, Ю.Г.Будникова, А.А.Карасик). Металл һәм металлфосфорорганик кушылмаларның яңа типлары синтезлана, аларның үзлекләре өйрәнелә, химик процесслар өчен утилизатор буларак файдалану мөмкинлекләре билгеләнә. Металлкомплекслы катализ углеводород чималын күкертле кушылмалардан чистартуның сәнәгый технологияләрендә (хезмәткәрләре б-н Ә.М.Мазһаров), синтетик каучукларны (СКЭПТ, СКИ-3, СКДН, СКДЛ), альфа-олефиннарны, полипропиленны, югары һәм түбән тыгызлыклы этиленны (Идел углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-ты, «Түбәнкаманефтехим» АҖ,«Казаноргсинтез» һ.б.) җитештерү технологияләрендә кулланыла. Э.к. өлкәсендәге тикшеренүләр б-н Казан ун-ты, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-ты, Казан технол. ун-ты галимнәре шөгыльләнә.

*Әд.:* Элементоорганические соединения: Интеграция химии на современном этапе // Соросовский образоват.журн. 1997. № 5; Э р н ш о А. Химия элементов: В 2 т. М.,2008; Э л ь ш е н б р о й х К. Металлоорганическая химия. М., 2011.

*Р.Ә.Черкасов.*

**«ЭЛЕМТӘ́»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б) ның Царицын губерна ком-ты органы. 1925 елның гыйнварыннан Царицын шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 4 саны чыга. Газета, социализм төзелешенә, кооперация үсеше һәм хуҗалык эшчәнлегенең башка мәсьәләләренә зур игътибар биреп, Царицын губернасы тормышын төрле яклап яктырта; анда чит илләрдәге крәстияннәр тормышы турында сөйләүче материаллар чагылыш таба. Коммунистик идеологияне пропагандалауга, элекке Россия империясе тәртипләрен, буржуазияне тәнкыйтьләүгә зур урын бирелә. «Э.» колхозлар оештыруга каршылык күрсәткән кулакларны кискен фаш итә, алар б-н нәтиҗәле көрәш үрнәкләрен китерә. 1 нче Бөтенсоюз укытучылар съезды эше турында мәгълүмат бирә. Басма битләрендә җирле авторларның карикатуралары, хикәяләре һәм шигырьләре, рус теленнән тәрҗемәләр (В.Маяковский һ.б.) басыла.

*З.З.Гыйләҗев.*

**ЭЛЕМТӘ́**, мәгълүматны төрле техник чаралар ярдәмендә тапшыру һәм кабул итү; икътисадның әлеге процессны гамәлгә ашыручы тармагы (к. *Земство почтасы*, *Казан шәһәр почтасы*, *Казан шәһәр телефон челтәре*, *Почта*, *Татарстан Республикасы*, *Спутник аша элемтә*, *Телеграф*, *Телефон челтәре*).

**ЭЛЕМТӘ́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасы буенда. 2010 елда 139 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 54%, татарлар — 43%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1933 тә «Овцевод» с-зы бүлекчәсе буларак нигез салына. Оешкан көненнән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1970 тә — 325, 1979 да — 242, 1989 да — 236, 2002 дә — 177 кеше.

**ЭЛИ́ЗИЯ** (лат. elisio — этеп чыгару), бер сүзнең ахырында һәм аннан соң килүче икенче сүзнең башында бертөрле сузыклар очрашканда, аларның берсе төшеп калу күренеше. Э. сузык+сузык авазлар тезмәсе хас булмаган татар телендә күзәтелә: кара урман [каºрурман], килә алмады [килалмады], шунда ук [шундуķ], юкмы әллә [йуķмәллә]. Ике бертөрле сузык аваз бергә туры килгәндә, аларның берсе генә әйтелә, ягъни авазлар кушылу күзәтелә: бара алмыйм [баºралмыйм], түлә әле [түләле].

Янәшә торган авазларның берсе югары күтәрелеш сузыгы (и, у, ү) булса, ике сүз бергә туры килгәндә, дифтонгоидлар яки ялган дифтонглар ясала: чи ит [чийит], үрә иден [үрәйден].

Э., нигездә, әйтелешнең сөйләм (тулы булмаган) стиленә туры килә һәм, алмагач (алма агачы), Каридел (Кара Идел елгасы), табагач (таба агачы), сарут (сары ут) кебек кушма сүзләр язылышын исәпкә алмаганда, орфографиядә чагылыш тапмый.

Ритм-рифма таләпләре буенча Э. күренеше язма рәвештә шигъри сөйләмдә дә күзәтелергә мөмкин: «Җиталмый, дуслар, җиталмый // Яратып сөйгән ярга».

*Әд.:* С а ф и у л л и н а Ф.С., З ә к и е в М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2002.

*Р.Ә.Закиров, Р.Х.Мөхиярова.*

**ЭЛЛЕ́РН** Семён Самуилович (29.6.1922, Казан — 26.7.1986, шунда ук), геолог-нефтьче, геол.-минерал. фән. канд. (1954). Казан ун-тын тәмамлый (1946), шунда ук укыта. Хезмәтләре нефть-газ барлыкка килү һәм туплану теориясенә, Татарстан һәм Көнчыгыш Себер терр-яләрендә битумнар, борынгы һәм яшь платформаларда углеводород ятмалары урнашу закончалыкларына карый. Э. углеводородларның формалашу һәм урнашу үзенчәлекләрен билгели, аларны эзләү һәм разведкалау методикасын эшли, ТР терр-ясендә девон утырмаларында брахиоподаларның яңа төрләрен ачыклый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЭЛМӘ́**, к а р а м а (Ulmus), элмәчәләр семьялыгыннан агачлы үсемлекләр ыругы. 30 дан артык (кайбер мәгълүматлар буенча 45 кә кадәр) төре билгеле. Нигездә, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендә табигый үсүче 2 төре бар: шома карама яки гади карама (U. laevis), шадра карама яки тау карамасы (U. glabra). Яфраклары гади, чиратлашкан, ике рәткә мозаик рәвештә урнашканнар, кыска саплылар; башка токымнарга караганда иртәрәк коелалар. Чәчәкләре күрексез, вак, ике җенеслеләр, җил б-н серкәләнәләр; бәйләмгә яисә башча чәчәк төркеменә җыйналганнар. Җимеше җиңелчә изелгәнрәк, элпә үсентеле озынча түгәрәк канатча. Яңадан төп үсентеләреннән һәм тамыр үрентеләреннән үрчи. 150–300 ел яши (аридлы шартларда 30–40 елга кадәр). Шома карама 25–30 *м* га кадәр биеклектәге, озын җепселле коңгырт-соры кабыклы агач. Ботаклары сыгылмалы, нәзек, ялтыравыклы. Яфраклары эллипс- яки кире йомыркасыман. Чәчәкләре шәмәхә-кызыл, кабарынкы




Шома карама:
1 — гомуми күренеше; 2 — язгы ботак.

бәйләмнәрдә. Күл буйларында, елга тугайларында, күбесенчә грунт сулары якын яткан, файдалы матдәләргә бай кәсле туфракларда үсә. Шадра караманың биеклеге 30 *м* га, диаметры 2 *м* га кадәр. Кәүсәсе куе көрән төстәге чатнаган кабыклы. Яфраклары кыска саплы, чите тигезсез, юка, кытыршы. Чәчәкләре шәмәхә, тыгыз шарсыман башча чәчәк төркемендә. Тигезлекләрдә, елга тугайларында үсә. Яшелләндерү өчен кулланыла, үзагачы агач эшләнмәләр җитештерүдә файдаланыла. Тәбәнәк Э. (U.pumila) Ерак Көнчыгыштан кертелгән. 16 *м* га кадәр биеклектә, ябалдашы чатырсыман формада, сары кабыклы. Яфраклары ланцетсыман, вак, тыгыз, өске ягы шома. Төрле туфракларда үсә ала. Туфракның тозлылыгын, ботакларын кыркуны җиңел кичерә. Яктылык яратучан, корылыкка, суыкка чыдам төр. Торак пунктларны яшелләндерүдә һәм урман полосалары булдыруда киң кулланыла. Кечкенә Э. (U. minor) Көньяк Европадан кертелгән. Культуралы үсемлек буларак сирәк үстерелә.

**ЭЛОДЕ́Я** (Elodea), субуярчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 18 төре билгеле, Американың уртача һәм тропик поясларында таралганнар. 19 йөздә Европага Канада Э.се (E. canadensis) кертелә, анда тиз арада һәм бик киң тарала (икенче «су чумасы» исеме шуннан). Ике өйле үсемлек. Барлык Европадагы кебек Татарстанда ана үсемлекләр генә очрый. Агымсыз




**Элпәканатлылар мәкаләсенә.** 1. Җирән нарат кисмәне (Niodiprion sertifer); 2. Зур яшел кисмән (Rhogogaster viridis); 3. Гади шөпшә (Parovespula vulgaris); 4. Ком аммофиласы (Ammophila sabulosa); 5. Җир казучы шөпшә (Bembix oculata); 6. Ялтырак шөпшә (Notozus pyrosomus); 7. Урман шөпшәсе (Dolichovespula silvestris); 8. Күк ялтырак шөпшә (Chrsis cyanea); 9. Гади зур шөпшә (Vespa craba); 10. Җирән урман чебене (Formica rufa) – канатлы ана зат, 10 а – эшче зат; 11. Кыр төклетурасы (Bombus agrorum); 12. Урман төклетурасы (Bombus silvarum); 13. Зур мөгезкойрык (Urocerus gigas); 14. Шәмәхә бал корты (Xylocopa violacea).

яки акрын агымлы сулыкларда үсә. 30–60 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыр системасы көчле түгел. Сабагы ботаклы, суга күмелеп үсә. Яфраклары ачык яшел, бер сабакка 3 әрдән бөжра рәвешендә урнашканнар. Чәчәкләре вак, озын чәчәк сапларында. Э. җимеш бирми. Бик сирәк, июнь-августта чәчәк ата. Вегетатив юл б-н үрчи. Аквариумнарда үрчетелә.

**ЭЛПӘКАНАТЛЫЛА́Р** (Hymenoptera), тулы әверелешле бөҗәкләр отряды. Иң күп санлы бөҗәкләрнең берсе — дөнья фаунасында 300 меңгә якын төре бар (өйрәнелгән төрләре буенча катыканатлылар отрядыннан гына калыша). Россиядә 6,5 мең төре, Татарстан терр-ясендә 300 дән артык төре билгеле. 21 *мм* дан 6 *см* га кадәр зурлыкта. Авыз аппараты кимерүче яки кимереп ялаучы типта. Канатлары элпә, аз гына сеңерчәле һәм күзәнәкле. Алгы һәм арткы канатлары үзара махсус ыргаклар б-н кушылып бербөтен канат өслеге хасил итәләр. Шулай ук канатсыз формалары да (кырмыскалар һәм кайбер паразитлар) бар. Аяклары йөгерүгә, йөрүгә яки казуга җайлашкан. Умарта кортларының аякларында кәрзиннән һәм кыллардан торучы җыю органы бар. Корсагы утырма яки сабаксыман. Ана затларның озын нечкә яки пычкысыман күкәй салгычы бар, чаккычларда ул укка әверелә яки бөтенләй юкка чыга (кырмыскаларда). Личинкалары аяксыз яки өч пар күкрәк һәм алты-сигез пар ялган корсак аяклы (кисмәннәр). Курчагы ирекле, еш кына ефәк яки тыгыз пергаментсыман кузы б-н капланган. Э. отряды 2 асотрядны берләштерә: утырма корсаклылар (Phytophaga) һәм сабаксыман корсаклылар (Apocryta). Иң гадиләре — утырма корсаклы Э. Аларның корсагы күкрәккә барлык алгы өслеге б-н тоташкан (сабаксыманнарда нечкә хәрәкәтчел буын б-н генә). Ата затлар парлашудан соң, ана затлар күкәй салганнан соң үләләр. Личинкалары ирекле яки үсемлек тукымаларында яши. Еш кына культуралы үсемлекләрнең, урман токымнарының корткычлары булып торалар. Татарстан терр-ясендә утырма корсаклылардан чын кисмәннәр, чукмармыеклы кисмәннәр һәм *мөгезкойрыклар* семьялыгы вәкилләре аеруча киң таралган (к. рәс.). Сабаксыман корсаклылар 2 төркемгә аерылалар: паразитлар (*җайдаклар, чикләвексыманнар*) һәм чагучылар (*шөпшәләр, умарта кортлары, кырмыскалар*). Җирән урман кырмыскасы урман санитары булып тора, зарарлы бөҗәкләрне юк итә. Бал кортларының берничә төре кыйммәтле продукт : бал, балавыз, *тома балавыз* (прополис), чыршын (перга) бирә. Күп кенә Э. — үсемлекләрне серкәләндерүчеләр. 25 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән (2016).

*Әд.:* Общая и сельскохозяйственная энтомология. М., 1983; Жизнь животных. М., 1984. Т. 3; Кадастр полезных насекомых Республики Татарстан. К., 2004. *Н.В.Шулаев.*

**ЭЛПИ́ДИН** Михаил Константинович (23.9.1835, Казан губ., Лаеш өязе Никольское а. — 1908, Каруж, Женева ш. бистәсе, Швейцария), революцион хәрәкәт эшлеклесе, журналист, нашир, мөхәррир. Руханилар катлавыннан. Чистай өяз дини уч-щесен тәмамлый (1855). 1855–60 елларда Казан өяз мәхкәмәсендә, Казан дәүләт милке палатасында хезмәт итә. 1860–61 дә Казан ун-тында ирекле тыңлаучы. 1861 нең апрелендә Казан губернасының Спас өязе Рус Бизнәсе авылында анда барган крәстиян чуалышлары б-н бәйле рәвештә кулга алына. 1861 нең көзендә Казанда студентлар хәрәкәтендә катнаша; университеттан куыла, Лаеш өязе Никольское авылына сөрелә. Казан революцион түгәрәге (1862 дән — «Земля и воля» җәмгыятенең Казан бүлеге) әгъзасы. 1863 тә *Казан фетнәсе* турында эш буенча икенче тапкыр кулга алына, 5 ел каторгага хөкем ителә. 1865 нең 7 июлендә Казан төрмә замогыннан кача, Швейцариягә эмиграциягә китә. Э. «яшь эмиграция» тарафдары, А.И.Герцен, Н.П.Огарёв көрәштәше һәм алар эшен дәвам итүче була. Огарёв фонды җитәкчесе; рус революцион оешмаларына зур күләмдә акчалар бүлеп бирә. 1867–76 да I Интернационалның Рус секциясе әгъзасы. 1866 да Э. Женевада рус басмаханәсен (1872 дә аны Цюрихка күчерә), 1881 дә китап кибете оештыра. «Подпольное слово» (№ 1–2, 1866), «Современность» (№ 1–7, 1868), «Народное дело» (№ 1–2, 1868) ж-лларын, «Общее дело» (№ 1–112, 1877–90) г-тасын нәшер итә. 1866–1906 да 200 гә якын исемдә китаплар, ш.и. Н.Г.Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә?» («Что делать?») романының беренче аерым басмасын (Женева, 1867) һәм әсәрләр җыелмасын (1–4 т., Женева, 1868–70), М.Е.Салтыков-Щедринның, Л.Н.Толстойның һ.б. цензура тарафынан тыелган әсәрләрен, ш.у. үзенең китап кибете каталогларын бастырып чыгара. Казанда 1860 еллардагы революцион хәрәкәт турында язмалар авторы.

Х е з м.: Казанский заговор // Колокол. 1865. № 205–206; Казань в осадном положении // Подпольное слово. 1866. № 2; Библиографический каталог. Профили редакторов и сотрудников. Женева, 1906.

*Әд.:* Пинаев М.М.К. Элпидин в 80–90-е гг.: Из истории русской эмиграции // Рус. литература. 1966. № 2; Ш у л у к. М.К.Элпидин — революционер, издатель, пропагандист Н.Г.Чернышевского // Уч. зап. Волгоград. пед. ин-та. 1967. Вып. 21; В у л ь ф с о н Г.Н., Н у р е е в а Ф.Ф. Братья по духу: Питомцы Казанского университета в освободительном движении 1840–1870 гг. К., 1989; Казанский университет (1804–1904): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1. *Е.Б.Долгов, В.А.Шагалов.*

**ЭМАНУЭ́ЛЬ** Николай Маркович (18.9.1915, хәзер Курск өлкәсенең Тим р-ны Тим пос. — 8.12.1984, Мәскәү), химия физигы, химия фән. д-ры (1949), СССР ФА академигы (1966, 1958 дән мөхбир әгъза), Социалистик Хезмәт Герое (1981). Ленинград политехник ин-тын тәмамлый (1938), СССР ФАнең Химик физика ин-тында эшли (1960 елдан химик һәм биол. процесслар кинетикасы секторы мөдире). Бер үк вакытта, 1944 тән, Мәскәү ун-тында, проф. (1950), СССР ФАнең Гомуми һәм техник химия бүлеге акад.-секретаре (1975 тән), СССР ФАнең химик кинетика һәм полимерларның картаюы буенча Гыйльми совет рәисе. Хезмәтләре химик реакцияләр кинетикасына һәм механизмына карый. Э. органик матдәләрнең сыек фазалы оксидлашуы процессларының теориясе һәм практикасы үсешенә, бу процессларның гомоген һәм гетероген катализаторлары, ингибиторлары тәэсире механизмын өйрәнүгә, полимерлар деструкциясе һәм стабильләшүе кинетикасын тикшерүгә өлеш кертә. Нефть химиясендә углеводородлар һәм башка органик матдәләрнең оксидлашу реакцияләреннән оригиналь файдалану юлларын таба. Углеводородларның газ фазалы оксидлашу реакцияләрен түбән температуралы сыек фазалы оксидлашу режимнарына күчерүнең яңа принцибын тәкъдим итә, бу исә максат итеп алынган продуктларның чыгышын арттыра. Альдегидларны газ фазалы оксидлаштыруга караган эшләре өчен СССР ФАнең А.Н. Бах исем. бүләгенә (1948) лаек була. Олефин окисьларын барлыкка китерү өчен иярешле чылбыр оксидлашу реакцияләреннән файдалану мөмкинлеген күрсәтә. Стабилизаторлар нәтиҗәлелеген тикшерү ысулларын һәм полимерларның төрле деструкцияләргә каршы чыдамлылыгын күрсәтүче микъдари критерийларны эшли. Эксперименталь һәм клиник онкологиядә ракны дәвалау нәтиҗәлелеген микъдари анализлау һәм шешләргә каршы препаратларның тәэсирен бәяләү өчен кинетик алымнар куллана. Шешләрнең башлангыч үсеше стадиясендә ирекле радикаллар процессы интенсивлашуы күренешен ача, шешкә каршы берничә препарат тәкъдим итә. Нурланыштан зарарлану очракларында ирекле радикалларның ролен тикшерә һәм (бергәлектә) ирекле радикаллы реакцияләр ингибиторларының саклау тәэсирен таба. СССР ФАнең 1941–44 тә Казанга эвакуацияләнгән Химик физика ин-ты составында оборона өлкәсенә караган фәнни эшләрдә катнаша. Күп кенә чит илләрнең фәнни академияләре әгъзасы. «Успехи химии» ж-лы баш мөхәррире (1971 дән). Ленин бүләге (1958), СССР МС бүләге (1977), СССР Дәүләт бүләге (1983) лауреаты. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе». Тынычлык һәм Дуслык (Венгрия) орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Н.М. Эмануэль.

Х е з м.: Цепные реакции окисления углеводородов в жидкой фазе. М., 1965 (автордаш); Кинетика экспериментальных противоопухолевых процессов. М., 1977 (автордаш); Химическая физика старения и стабилизации полимеров. М., 1982 (автордаш).

*Әд.:* Николай Маркович Эмануэль // Материалы к биобиблиографии учёных СССР. Сер. хим. наук. М., 1976. Вып. 58; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991; БСЭ. 3 изд. М., 1978. Т. 30.

**ЭМИГРАНТЛА́Р МАТБУГАТЫ́.** 1905–45 елларда һәм Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Төркия, Венгрия, Германия, Финлян-

дия, Швеция, Румыния, АКШта татар телендә нәшер ителгән газеталар һәм журналлар.Чит илләрдә милли матбугатны оештыручылар — 1917 елгы Окт. рев-циясенә кадәр һәм совет хакимиятенең беренче елларында Россиядән эмиграциягә киткән татар интеллигенциясе вәкилләре, җәмәгать, дин эшлеклеләре, аларның балалары, ш.у. Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышы вакытындагы хәрби әсирләр. Беренче басмалар Төркиядә дөнья күрә. Алар арасында: Истанбулда — «Казан», «Мизан», «Өч кардәш», «*Тәгарифе мөслимин*», «*Түрк юрду*», «Халыкка тугры», «Ислам дөньясы», «Тәгавын ислам», «Галләм ислам», «Тукай бюллетене» һәм «*Казан*», Әнкарада — «Идел-Урал».

Беренче бөтендөнья сугышы барышында татар телендәге газеталар Австро-Венгрия һәм Германия терр-ясендәге сугыш әсирләре лагерьларында барлыкка килә. 1915–16 да Венгриянең Эстергом шәһәре янында (Будапешт тирәсендә) мөселман әсирләре өчен кулъязма «Кечерәк җуаткыч» яшерен әдәби-фольклор г-тасы чыга. 1915–20 дә *Вюнсдорф лагеренда* 5 газета басыла. Германиядә дә газета-журналлар нәшер ителә: Берлинда — «әл-Җиһад әл-ислам», «*әл-Җиһад*», «Яңа тормыш», «*Татар иле*», «*Азат Шәрекъ*», «Милли юл», «*Яңа милли юл*», «Идел-Урал», «Түрк бирлиги. Идел-Урал», «Татар әдәбияты», «*Германча-татарча белешмә* — Дойче-татаришес нахрихтенблат», Ной Ульмеда — «Очар яфраклар» , Мюнхенда — «*Азат Ватан*», «Безнең фикер», «Таң йолдызы» һәм «Урал авазы». Басманың дәвамлылыгы, авторлар коллективы составы, материаллар тематикасы төрлелеге буенча Э.м. арасында «Милли юл» ж-лы аерым урын алып тора, аның баш мөхәррире күренекле язучы Г.Исхакый була. 21 йөз башында Франкфурт-Майнда «Бертуган» (2002–10) ж-лы басыла, 2004 тән Германия татарлары берлеге «АлТаБаш» интернет-ж-лы чыгара.

Польшада (Вильно ш., хәзерге Литва) 1934–39 да поляк телендә «*Жиче татарске*» ж-лы нәшер ителә, аның авторлар коллективын Польша-Литва татарлары тәшкил итә. Журнал 1998 нең сентябрендә Сосулки шәһәрендә (Польша) кабат чыга башлый. 1932, 1935 һәм 1938 дә Вильно, Замостье һәм Варшавада поляк телендә «Рочник татарски» ж-лы дөнья күрә; 1993 тән Гданьск шәһәрендә кабат басыла.

Ерак Көнчыгышта беренче басмалар 1920 еллар башында Харбин шәһәрендә барлыкка килә, анда күп кенә татар эмигрантлары яши. Баштарак алар кулъязма рәвешендә була яки гектографик яисә ташбасма ысулы б-н күбәйтелә. 1927 дә төрек язуын латин язуына күчерү б-н бәйле рәвештә гарәп басмаханә шрифтларының арзан базары барлыкка килә. Татар эмигрантлары аларны сатып ала һәм Кытай б-н Япониягә алып килә. Иң беренче басма «*Ерак Шәрекъ*» ж-лы була, аны 1920–22 дә Харбинның татар җәмгыяте чыгара; 1924–25 тә журнал шул ук исемдәге газета булып нәшер ителә. Кытайда вакытлы матбугат: Харбинда — «Ялкын», «Пилмән», «Чаткы», «Тәммүз», беркөнлек газеталар — «Мең ел», «Шагыйрь», «Бәйрәм нуры», Тяньцзинь шәһәрендә — «Йолдыз», «Шәрекъ авазы», Мукденда — «*Азат Шәрекъ*» «Шәкертләр таңы», «*Милли байрак*» һәм «Ерак Шәрекъ төрек-татар мөселманнарның корылтае» бюллетене чыгарыла. Кытайның Шөнҗан-Уйгыр автономияле р-ның Өремче, Голҗа, Тарбагатай шәһәрләрендә татар журналистлары катнашында уйгыр телендә « Бизнин Ватан», «Азад Шәрки Төркистан», «Шөнҗан газеты», «Алга», «Ак су» һ.б. г-талар басыла.

1931–45 тә Япониядә дә татар телендә вакытлы матбугат чыга. «Яңа япон мөхбире» ж-лына нигез салучы һәм беренче мөхәррире Токиода «Матбугаи исламия» басмаханәсен оештырган М.Корбангалиев була. Басмаханәдә татар телендә китаплар, газеталар, журналлар һәм календарьлар басыла. Япониядә «Рәсемнәр мәҗмугасы» ж-лы, «Игълани хакыйкать» һәм «Берлек мәҗмугасы» г-талары нәшер ителә. Кобе шәһәрендә «Япон императорлыгында яшәүче төрек-татар мөселманнарының булачак корылтаена хәзерләнү хакында» бюллетененың 5 саны басыла.

1920 елларда Финляндия татарларының вакытлы матбугаты барлыкка килә башлый. 1925 нең 16 гыйнварында Кеми шәһәрендә язучы Х.Хәмидулла «Мәгърифәт» г-тасын чыгарырга керешә. Кеми, Хельсинки, Тампере, Оулу шәһәрләрендә төрле елларда «Шималь очкыннары», «Туран», «Белдереш», «Мәхәллә хәбәрләре», «Тавыш», «Ак юл» г-та һәм ж-ллары дөнья күрә. 1967 дә Стокгольмда мөселман җәмгыяте үзенең «Безнең фикер» ж-лын бастыра.

Хәзерге вакытта Американың Сан-Франциско шәһәрендә «Яңалыклар» г-та-бюллетене нәшер ителә (элеккеге исеме — «Хәбәрләр мәктүбе»). Румыниянең Добруджа шәһәрендә татар укучылары «Кара диңгез» г-тасы һәм «Рәнәкләр» ж-л-альманахын алдыра.

1905 тән чит илләрдә татар телендә 70 кә якын басма чыга, аларның күбесе Германиядә (17), Кытайда (15), Төркиядә (14), Финляндиядә (6), Япониядә (5) басыла. Чит ил татар матбугатында татарларның тарихи үткәне, аларның дәүләтчелеге мәсьәләләре яктыртыла; күренекле җәмәгать, дәүләт һәм дин эшлеклеләре, әдәбият, сәнгать вәкилләре, диаспораның социаль-икътисади һәм рухи-мәдәни тормышы турындагы материаллар урнаштырыла. Октябрьдән соңгы матбугат большевикларга каршы позициядә тора: Россиядәге динне эзәрлекләүне, крәстияннәрне көчләп күмәкләштерү, руслаштыру сәясәтен (аерым алганда, татар һәм башка халыкларның язуын кириллицага күчерү), массакүләм сәяси репрессияләрне тәнкыйтьли, соц. экспериментның перспективасызлыгын алдан белдерә. СССРда Э.м. тарату катгый тыела һәм эзәрлекләнә.

*Әд.:* Т а һ и р М. Чит илләрдәге татар вакытлы матбугаты // Казан утлары. 1990. № 10; М и ң н е г у л о в Х.Й. Чит илләрдә татар әдәбияты. К., 2007; Г а й н е т д и н о в Р.Б. Тюрко-татарская политическая эмиграция: начало XX века — 30-е годы. Наб. Челны, 1997; Г и л я з о в И. На другой стороне (Коллаборационисты из поволжско-приуральских татар в годы Второй мировой войны). К., 1998; Н а с ы р о в Т. Татарская эмигрантская пресса // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2004 № 2.

*Т.М.Насыйров.*

**ЭНӘКАРАКЛА́Р** (Odonata), бөҗәкләр отряды. Карбон чорыннан билгеле. Озынлыгы 14 тән 120 *мм* га, канат җәеме 100 *мм* га кадәр. Гәүдәсе төз,сузынкы, кайвакыт ачык төстә. Зур башлы, авыз аппараты кимерүче типта. Күзләре дә зур, ул башының шактый өлешен били. Мыекчалары кечкенә. Канатлары челтәрсыман, күпсанлы сеңерчәле һәм күзәнәкле. Дөнья фаунасында якынча 4,5 мең төре бар, күбесенчә тропикларда таралганнар. Россиядә якынча 200 төре, Татарстан терр-ясендә 40 лап төре (тигезканатлылар — Zygoptera һәм төрлеканатлылар — Anisoptera асотрядлары) билгеле. Олы Э. яхшы очалар. Актив ерткычлар, күбесенчә икеканатлылар (озынборыннар һ.б.) б-н тукланалар, корбанын һавада очканда ук тота. Үсеше тулы булмаган әверелешле. Парлашу һавада бара. Ана зат күкәйләрен грунтка яки үсемлеккә — суда сала. Личинкалары суда үсә, ерткычлар; азык эләктерү өчен хезмәт итүче хәрәкәтчел казналык (битлек) аларның үзенчәлекле билгесе булып тора. Корсагының арткы очында урнашкан саңаклар яисә арткы тишем аша әчәкләр б-н сулый. Соңгы тапкыр кабыгын салыр алдыннан личинка судан чыга һәм һавада кабыгын салып канатлы олы бөҗәккә әверелә. Төрле бөҗәкләрнең санын көйләүдә Э. гамәли әһәмияткә ия. Личинкалар, балык маймычларын юк итеп, балык хуҗалыкларына зыян китерергә мөмкиннәр. Татарстанда аеруча *ялтыравык чикерткә*, сары энә карагы (Sumpetrum flaveolum), лютка-дриада (Lestes dryas), чибәркәй энә карагы (Coenagrion puella) таралган (к. *Уклар*). 2 төре: *зур энә карагы* һәм чибәркәй энә карагы (Calopteryx virgo) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Н.В.Шулаев.*

**Э́НВАЛЬД** Николай Григорьевич (22.2.1928, Украина ССР, Котовск р-нының Деконщина а. — 14.08.2016, Казан), дәүләт эшлеклесе, РСФСРның атказ. механизаторы (1978), РСФСР Дәүләт бүләге лауреаты (1990). Ленинград а.х.ын механикалаштыру һәм электрлаштыру ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Чистай р-нында эшли: МТСта баш инженер, ремонт-техник станция директоры, «Райсельхозтехника» берләшмәсендә идарәче (1957 елдан). 1964–85 тә «Татсельхозтехника» ЖБ рәисе. 1985 тән ТАССР МС рәисенең беренче урынбасары, бер үк вакытта, 1990 нан Дәүләт агросәнәгать ком-ты рәисенең беренче урынбасары, рәисе. Бер үк вакытта, 1990–93 тә, ТССР А.х. һәм азык-төлек министрлыгының тышкы багланышлар бүлеге башлыгы. Татарстан а.х. җитештерүен механикалаштыру дәрәҗәсен күтәрүгә, җирле чимал материалларын кулланып ачы туфракка известь кертү буенча чаралар оештыруга, 2 млн. *т* известь чыгаруны тәэмин итүгә, сугару системаларын төзүгә (елына 30 мең *га*), «Татария» сугару комплексын эшләүне үзләштерүгә һәм «Татария» төзелеш модулен булдыруга зур өлеш кертә. 1966–90 да ТАССР, 1990–91 дә ТССР, 1992–95 тә ТР ЮСлары депутаты. Октябрь

Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Орошаемые сенокосы и пастбища Татарии. К., 1979 (автордаш).

**ЭНГЕЛЬГА́РДТ** Александр Платонович (14.8.1845, Смоленск губ., Духовщина өязе Климово а. — 22.11.1903, Берн, Швейцария), дәүләт эшлеклесе, икътисадчы, яшерен советник (1902). Дворяннар нәселеннән. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1867). 1867–90 елларда Смоленск шәһәрендә: губерна дворяннар җыены секретаре (1872 гә кадәр), 1872 дән губерна төрмәләр буенча попечительләр ком-ты директоры, бер үк вакытта, 1877 дән шәһәр башлыгы. 1890–93 тә Казан вице-губернаторы. Иген уңмаган 1891–92 дә һәм 1892–93 тәге ваба эпидемиясе вакытында Казан губернасы халкына ярдәм оештыручыларның берсе. 1893–1901дә Архангельск, 1901–03 тә Саратов губернаторы. 1903 тә игенчелек һәм дәүләт милке министры иптәше (урынбасары). «Терлекләрне мүк белән тукландыру тәҗрибәләре» («Опыты кормления скота мхами», 1891), «Казан һәм Урта Иделнең башка губерналарындагы крәстиян хуҗалыгы турында очерк» («Очерк крестьянского хозяйства в Казанской и других средневолжских губерниях», 1892) һ.б. хезмәтләрендә 19 йөз ахырында Казан губернасындагы крәстиян хуҗалыкларының икътисади хәлендә анализ ясый һәм төбәктә а.х.ның интенсив үсеш юлларын билгели. Хезмәтләре Рус Төньягын, Россиянең кара туфраклы төбәкләрен икътисади үзләштерүгә карый.

Х е з м.: Русский Север: Путевые заметки. СПб., 1897; Чернозёмная Россия: Очерк экономического положения края. Саратов, 1902.

*Әд.:* Л о б а н о в - Р о с т о в с к и й А.Б. Русская родословная книга. СПб., 1895. Т. 2; П о п о в Г.П. Губернаторы Русского Севера. Архангельск, 2001. *Е.Б.Долгов.*

**ЭНГЕЛЬГА́РДТ** Василий Павлович (29.7.1828, Смоленск ш. — 6.5.1915, Дрезден ш., Германия), астроном, Петербург ФА мөхбир әгъзасы (1890 елдан). Казан ун-тының астрономия шәрәфле д-ры (1889). Петербург хокук уч-щесен тәмамлый (1847). Сенатның 1 нче һәм 5 нче департаментында хезмәт итә (1853 кә кадәр). Астрономияне үзлегеннән өйрәнә. 1872 дән Дрезденда. 1879 да астрономия обсерваториясен төзи, кушма йолдызларны, томанлылыкларны һәм кече планеталарны күзәтә. «В.Энгельгардтның Дрездендагы үз обсерваториясендә уздырган астрономик күзәтүләре» («Observations astronomiques, faites par V.d'Engelhardt a son Observatoire a Dresde», т. 1–3, 1886–95) хезмәте авторы. 1890 елларда үз обсерваториясенең барлык астрономик инструментларын Казан ун-тына бүләк итә. 1901 дә Казан янында Э. акчасына обсерватория төзелә (1931 дән Э. исемен йөртә). Э. Петербургның Җәмәгать китапханәсенә М.И.Глинканың кулъязмалар җыелмасын тапшыра. Композиторның вафатыннан соң аның опералары һәм башка әсәрләренең партитураларын бастырып чыгара. Рус полководецы А.В.Суворовның Швейцариягә походы турында материаллар җыю б-н шөгыльләнә (1812 елгы Ватан сугышының 100 еллыгы уңаеннан Петербургтагы Суворов музеена тапшырыла). 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә. Айдагы бер кратер Э. исеме белән атала.

*Әд.:* М а р т ы н о в Д.Я. Василий Павлович Энгельгардт (к 150-летию со дня рождения) // Земля и Вселенная. 1978. № 4. *Р.Г.Усманов.*

**ЭНГЕЛЬГА́РДТ** Владимир Александрович (21.11.1894, Мәскәү — 10.7.1984, шунда ук), биохимик, химия фән. д-ры (1929), СССР Медицина фәннәре академиясе (1944) һәм СССР ФА академигы (1953; 1946 елдан мөхбир әгъза), Социалистик Хезмәт Герое (1969). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1919). 1921–29 да Сәламәтлек саклау халык комис-тының Биохимия ин-тында эшли. 1929–33 тә Казан ун-тының мед. ф-ты биохимия каф. мөдире. Ленинград (1934–40) һәм Мәскәү (1936–59) ун-тлары профессоры. Бер үк вакытта СССР ФАнең Биохимия ин-тында (Мәскәү, 1935–59) һәм Физиология ин-тында (Ленинград, 1944–50) хайван күзәнәге биохимиясе лаб-ясе мөдире, СССР Мед. фәннәре академиясе эксперименталь мед. ин-тында биохимия бүлеге мөдире (Ленинград, 1945–52). СССР ФАнең Молекуляр биол. ин-ты (хәзер Э. исемен йөртә) оештыручы һәм директоры (1959 елдан). СССР ФАнең Биол. фән. бүлеге акад.-секретаре (1955–59). Илдә молекуляр биологиягә нигез салучыларның берсе. Э. сулау фосфорилирлавы процессын (Казан) һәм (М.Н.Любимова б-н бергә) миозинның ферментатив активлыгын ача. Сулау б-н әчү процессларының үзара тәэсир итешүе физиол. механизмын (Пастер эффекты) аңлатып бирә. Витаминнар һәм аденозинтрифосфор к-тасын җитештерүнең химизмен һәм технологиясен тикшерүгә, нуклеин к-талары, аксымнар биосинтезы ферментларының структурасын һәм функциясен өйрәнүгә өлеш кертә. Кире транскрипция («Ревертаза» проекты) буенча тикшеренүләр оештыра. Э.ның эритроцитлар алмашына багышланган эшләре кан консервацияләүнең теориясе һәм практикасы өчен нигез була, әчү һәм сулау процессларын бәйлелектә тикшерүләре микробиологиядә, сәнәгатьтә, медицинада кулланыш таба. Күп кенә чит ил фәннәр академияләре һәм гыйльми җәмгыятьләрнең әгъзасы. «Биохимия» ж-лы баш мөхәррире (1944 тән), «Молекулярная биология» ж-лына нигез салучы һәм аның баш мөхәррире (1966 дан). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1943, 1979). Биш Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары; медальләр, ш.и. СССР ФАнең М.В. Ломоносов исем. алтын медале, ш.у. чит илләрнең орденнары һәм медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Окислительный распад фосфоглюконовой кислоты // Биохимия. 1938. Т. 3, вып. 4 (автордаш); Фосфорная кислота и функции клетки // Изв. АН СССР. Сер.биол. 1948. № 2; Поверхностно локализованная аденозинполифосфатаза (эктоапираза) ядерных эритроцитов. М., 1955 (автордаш); Молекулярная биология // Развитие биологии в СССР. М., 1967.



В.П.Энгельгардт.



В.А.Энгельгардт.

*Әд.:* В о л к о в Р.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр.справ. М., 1991; БСЭ. 3 изд. М., 1978. Т. 30.

**ЭНГЕЛЬГА́РДТ АСТРОНО́МИЯ ОБСЕРВАТО́РИЯСЕ**, к. *Астрономия обсерваториясе.*

**ЭНДОКРИНОЛО́ГИЯ** (грек. endon — эчке, krino — бүлеп чыгару, аеру һәм ... *логия*), клиник мед. өлкәсе, эчке секреция бизләренең үсешен, төзелешен, функцияләрен, гормоннарның физиол. тәэсире механизмнарын өйрәнә, эчке секреция бизләре системасы авыруларына диагноз кую, аларны дәвалау һәм кисәтү ысулларын эшли. Казанда калкансыман биз авырулары беренче тапкыр 1840 елларда К.Ф.*Фукс* тарафыннан өйрәнелә башлый. Казанның шәһәр табибе Н.А.*Толмачёв* зобны төбәк авыруы буларак тасвирлый («Казан губернасындагы зоб турында» — «О зобе в Казанской губернии», 1864). Казан ун-ты галимнәре М.Ф.Кондаратский (1889), М.В.Казанцев (1899), В.И.*Разумовский*, Л.О.*Даркшевич*, Н.А.*Геркен*, А.Н.*Казимбәк*, В.В.Пашутин, М.Н.*Чебоксаров*, А.Г.Суворов (1926), М.Н.Андреев (1927), Г.И.Арнт (1933), А.А.Полянцев һәм А.И.Полянцева, И.Ф.Крупачёв (1935), В.В.*Милославский* (1927–57) бу проблеманы Урта Идел, Урал буе зоналарына бәйләп өйрәнүгә аерым хезмәтләр багышлыйлар.

С 1950 елларда ТАССРда зоб эндемиясен комплекслы өйрәнү башлана, ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы (рәисе В.В.Милославский, 1955) һәм Респ-ка клиник хастаханәсе (1960) каршында зобка каршы көрәш ком-тлары төзелә. 1961 дә ТАССР МС каршында Эндемик зобка каршы көрәшнең гамәли чараларын координацияләү ком-ты оештырыла (рәисе И.З.*Мөхетдинов*). Казан (1961), Лениногорск (1962) шәһәрләрендә зоб диспансерлары, Казан шәһәре поликлиникалары һәм респ-ка район хастаханәләре каршында Э. кабинетлары, ш.у. 6 нчы шәһәр хастаханәсе (Казан) базасында Э. бүлеге (1963) ачыла.

В 1960–70 елларда респ-када эндемик зобны өйрәнүне В.В.Милославскийның шәкертләре — С.С.Шульпинов, А.Н.Юнысова, В.П.*Камчатнов*, Г.М.Гыйльманова, А.Т.*Гончаров*, А.М.*Хәкимова*, Ф.Г.Таҗетдинова, Ю.К.Разумовский, М.Х.Газыймова, М.М.Мельникова, О.А.Королькова һ.б. дәвам итә. Авыруларга махсус ярдәм күрсәтү өчен 1974 тә Респ-ка зоб диспансеры (баш табиб Э.Н.Хәсәнов), Респ-ка клиник хастаханәсендә 40 ятак-урынга исәпләнгән Э. бүлеге (1982, беренче мөди-

ре Е.А.Добрынина) ачыла. Бу бүлек Казан мед. ун-тының Э. кафедрасы өчен (1976 да ачыла, беренче мөдире В.В.*Талантов*; 2015 тән — Ф.В.*Вәлиева*) уку-укыту базасы булып тора. 1977 да зоб авырулы балаларны дәвалау өчен Респ-ка балалар клиник хастаханәсендә 15 ятак-урын билгеләнә (1994 тән — 35 ятак-урынлы аерым Э. бүлеге).

Казан галимнәре тарафыннан шикәр диабеты очрагында икенчел метаболик һәм гормональ тайпылышлар, аларның катлаулану механизмнарындагы роле, бу тайпылышларны коррекцияләү юллары тикшерелә; «Бөер өсте бизләренең минерал-кортикоид функциясе, шикәр диабеты б-н авыручыларда авыруның җитдилек һәм декомпенсация дәрәҗәсенә бәйле рәвештә натрий һәм калий алмашы» («Минералокортикоидная функция надпочечников, обмен натрия и калия у больных сахарным диабетом в зависимости от степени тяжести и степени декомпенсации заболевания», Э.Н.Хәсәнов, 1976), «Диабетик нефропатиянең көчәюе барышында мембрана тайпылышларының әһәмияте» («Значение мембранных нарушений в развитии прогрессирования диабетической нефропатии», Ф.В.Вәлиева, 2005), «1 нче тип шикәр диабеты булган диабетик нефропатияле авыруларның эритроцитларында Na/Li күчешенә каршы халәт» («Состояние Na/Li противотранспорта в эритроцитах у больных сахарным диабетом 1 типа с диабетической нефропатией», Р.А.Надиева, 2006), «2 нче тип шикәр диабеты булган авыруларда метаболик фермент системалары һәм аларны ксимедон белән фармакологик коррекцияләү» («Метаболические ферментные системы у больных сахарным диабетом 2-го типа и их фармакологическая коррекция ксимедоном», Т.А.Киселёва, 2007) хезмәтләре язылы.

1996 да Казан мед. академиясендә (Казан тимер юл станциясе хастаханәсе базасында) Э. каф. ачыла (мөдире Л.И.*Анчикова*). Кафедра хезмәткәрләре тарафыннан калкансыман биз патологияләренә ультратавыш допплерографиясе ярдәмендә дифференциаль дигноз кую ысуллары (Г.Р.Ваһапова), аутоиммун тиреоидитны дәвалауда илдә уйлап табылган оригиналь димефосфон препаратын куллану алымнары (Л.И.Анчикова, Л.Н.Куршакова, А.О.Поздняк), кискен тиреоидит һәм дәвалауга бирешмәүчән авыр аутоиммун тиреоидит очрагында фонофорез һәм диметилсульфоксид ярдәмендә калкансыман бизнең үзенә глюкокортикоидлар кертү ысулы (Г.Р.Ваһапова, Т.В.Никишова) тәкъдим ителә. Татарстанда яшәүчеләрнең калкансыман биз авырулары очракларында беренчел һәм икенчел йод кытлыгының роле өйрәнелә; зоб үсешенә микроэлементлар җитешмәү һәм артык булуның тәэсире ачыклана. Энтеросорбентлар (микрокристаллик целлюлоза, «Днепр» препараты) һәм составында микроэлементлар булган дарулар куллану буенча тәкъдимнәр эшләнә (С.С.Кривошеева, О.П.Гребнева). Үт куыгы алынган шикәр диабетлы авыруларга диагноз куюның яңа ысуллары һәм дәвалау тактикасы гамәлгә кертелә. Ел саен кафедрада ординаторлар, интерннар, аспирантлар, дәвалаучы табибләр белем ала.

2000 еллардан башлап ТРда Э. хезмәте 3 зоб диспансеры, Респ-ка клиник хастаханәсе, Казан шәһәре 7 нче клиник хастаханәсе, Респ-ка балалар клиник хастаханәсендәге Э., диабетология үзәкләре һәм бүлекләре, ТР шәһәрләре поликлиникалары каршындагы Э. кабинетлары аркылы күрсәтелә. Шикәр диабетлы авырулар өчен бер көнлек стационарлар, диабет мәктәбе һ.б. оештырыла. Респ-када Э. хезмәтенең үсеш дәрәҗәсе авыруларны дәвалау һәм оештыру эшләренә караган катлаулы мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек бирә, ләкин эндемик зобны бетерү сәламәтлек саклау өлкәсендәге актуаль мәсьәлә булып кала.

*Әд.:* Т а л а н т о в В.В. Эндемический зоб: Сущность. Экология и генетика в этиологии. Дефиниция // Проблемы эндокринологии. 1989. № 4; К проблеме сахарного диабета в Республике Татарстан. К., 1997; А н ч и к о в а Л.И. Неотложная помощь больным сахарным диабетом с острыми осложнениями. К., 2009; История развития эндокринологии в Республике Татарстан // Сахарный диабет. 2014. № 2. Т. 17; Краткая медицинская энциклопедия. М., 1974. Т. 1.

*Ф.В.Вәлиева.*

**ЭНЕОЛИ́Т** (лат. aeneus — бакыр һәм грек lithos — таш), таш гасырдан бакыр гасырга күчеш чоры (б.э.к. 4–3 нче меңьеллыклар). Таш кораллар өстенлек итә, бакырдан эшләнгәннәре тарала башлый. Халыкның төп шөгыльләре — китмәнле игенчелек, терлекчелек, сунарчылык. Көнчыгыш Европада беренче бакыр эшләнмәләр б.э.к. 4 нче меңьеллыкта барлыкка килә. Татарстан терр-ясендә Идел-Чулман төбәге халкының иң элгәре чорларда Э. эшләнмәләрен куллануы Мурзиха II каберлегендәге каберләрнең берсендә бакыр балдак табылуда чагыла (бизәнү әйбере, б.э.к. 4 нче меңьеллыкның 2 нче яртысы; Балык Бистәсе р-ны, 1995, А.А.Чижевский). Каберлектә ш.у. таштан, сөяктән эшләнгән эш һәм сугыш кораллары (ук һәм кыска сөңге очлыклары, хәнҗәрләр, гарпуннар, балталар һ.б.), таштан ясалган бизәнү әйберләре, кабырчыклы сәйлән, гәрәбә муенса, сөяк һәм чакматаш сыннар, тарак теше рәвешендәге бизәк төшерелгән касәсыман кечкенә савытлар, мөгезле эре терлек сөякләре һ.б. табыла. Элегрәк аларга охшаш материаллар Тенеш (Кама елгасы тамагы, Р.С.Габәшев) һәм Гулькин (Үтәк елгасы тамагы, А.В.Збруева) каберлекләрендә казу эшләре вакытында очрыйлар. Көньяк р-ннардан аермалы буларак, Татарстан терр-ясендә бакыр эш кораллары барлыкка килү җирле халыкның хуҗалык эшчәнлегендә кискен үзгәрешләргә һәм җитештерүчән икътисадка күчешкә китерми. Элеккечә үк таш эш һәм сугыш кораллары киң кулланыла, бакыр әйберләр сирәк очрый. Э. чорында терлекчелек һәм примитив игенчелек яралгылары барлыкка килә. Кагыйдә буларак, торулыклар (туктаулыклар) биол. ресурсларга бай елга тамаклары тирәсендә, елга үзәннәрендә урнашалар. Татарстан терр-ясендә табылган әйберләр килеп чыгышлары, балчык савыт-сабаның эшләнеш һәм бизәлеш үзенчәлекләре, бакыр эшкәртү технологиясен үзләштерү дәрәҗәсе буенча берничә культура төркеменә бүленәләр. Рус Әҗбие туктаулыкларының тарак теше сыман бизәк төшерелгән керамик эшләнмәләре *Чулман буе культурасына* (б.э.к. 7–4 нче меңьеллыклар) якын; Татар Әҗбие II туктаулыгының тишекле-сызыклы һәм флагсыман бизәкләр төшерелгән балчык савыт-сабасы башка төркемне хасил итә һәм, фаразланганча, ул Көнчыгыш Европаның урман-дала һәм дала зонасы халкы тарафыннан калдырылган. Охшаш әйберләр комплекслары Килдураз (Зөя елгасы), Питрәч (Мишә елгасы), Игим, Золотая Падь һ.б. туктаулыкларда табыла. *Волосово культурасы* (б.э.к. 3 нче меңьеллык ахыры — б.э.к. 2 нче меңьеллыкның 1 нче яртысы) һәм *Гарино-Бор культурасы* (б.э.к. 3 нче меңьеллык — б.э.к. 2 нче меңьеллык уртасы) истәлекләре Э.ның төгәлләүче этабы булып тора. Б.э.к. 3 — 2 нче меңьеллыклар чигендә Көнчыгыш Европаның урман-дала һәм урман полосаларына бакыр һәм аккургаш катнашмасы, бу катнашмадан алынган бронзадан ябык формаларда төрле эшләнмәләр коюу технологиясе үтеп керә (к. *Бронза гасыр*).

*Әд.:* Энеолит лесного Урала и Поволжья: Материалы II полевого симпозиума по проблемам археологии эпохи камня — бронзы лесной полосы Европейской части СССР. Ижевск, 1990; Г а б я ш е в Р.С. Энеолит Нижнего Прикамья // Очерки по археологии Татарстана: Учеб. пособие для студентов вузов и учителей истории. К., 2001; ш у л у к. Население Нижнего Прикамья в V–III тысячелетиях до нашей эры. К., 2003; Ч и ж е в с к и й А.А. Погребения эпохи энеолита Мурзихинского II могильника // Тр. II (XVII) Всероссийского археологического съезда в Суздале. М., 2008. Т. 1.

*М.Ш.Галимова.*

**«ЭНЕРГОБАНК»**, акционерлык коммерция банкы. 1989 елда Казанда Татарстан коммерция банкы буларак оештырыла. 1993 тән хәзерге исемдә. «Эдельвейс Корпорейшн» АҖ — банкның иң эре акционеры. «Э.» һәм аның ф-лары 10 меңгә якын корпоратив клиентка хезмәт күрсәтә, алар арасында респ-каның иң алдынгы пр-тиеләре һәм оешмалары, кече һәм урта бизнес вәкилләре һәм эшмәкәрләр бар. Банк, башлыча, ТР икътисадының реаль секторын финанслый. 2017 дә кредит күләме 3,1 млрд. сум, банкка акча салучы физик затларның акчасы 6,1 млрд. сумнан артык. «Экспорт» рейтинг агентлыгы банкның тиешле дәрәҗәдә кредит бирү сәләтен раслый. Банкның активы 22,3 млрд. сум; нетто активы рейтингы буенча Россиядә 151 нче, ә ТРда 7 нче урында. «Интернет-Клиент», «Выписка Онлайн», «Телефакс-Клиент» һ.б. хезмәтләр кертелә. «Э.» Россия һәм Татарстан банклар ассоциацияләре, Халыкара банк системасының SWIFT телекоммуникацияләр ассоциациясе, Мәскәү банкара валюта биржасы һ.б. әгъзасы. 2017 нең 1 гыйнварына банкның устав капиталы — 2137,1 млн. сум, үз капиталы — 4097,2 млн. сум. 2017 дә табышы — 362,2 млн. сум.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ЭНТОМОЛО́ГИЯ** (грек. entoma — бөҗәкләр һәм *...логия*), *бөҗәкләрне* өйрәнүче фән, зоологиянең зур бүлеге. Биологиядә мөһим бүлекләрнең берсе булып тора, чөнки 3 млн.нан артык төрне (башка мәгълүматлар

буенча Җир шарында 10 млн.нан артык төр бар) берләштерүче бөҗәкләр тере организмнарның иң зур систематик төркемен тәшкил итәләр. Бурычлары буенча гомуми һәм гамәлигә бүленә. Гомуми яки теоретик Э. бөҗәкләрнең төп үзенчәлекләрен: гәүдә төзелешен, систематикасын, тереклек рәвешен, яшәү тирәлеге б-н бәйләнешен (экология), физиологиясен, биохимиясен өйрәнә. Гамәли фәннәргә а.х. Э.се (тикшерү объектлары — басу, җиләк-җимеш һәм яшелчә культуралары корткычлары), урман (урман үсемлекләре корткычлары), мед. (кешеләрдә йогышлы авырулар таратучылар), вет. (йорт хайваннары паразитлары), ш.у. мәхкәмә Э.се (мәхкәмә-мед. экспертизасы үткәргәндә үлем вакытын билгеләү өчен үләксә бөҗәкләрен файдаланалар) кертелә. Э.нең башка тармаклары — *умартачылык* һәм ефәкчелек.

Э.нең фән буларак формалаша башлавы 17 йөзгә карый: бу вакытта Голландия галиме Я.Сваммердам һәм Италия галиме М.Мальпигиның анатомия һәм бөҗәкләр метаморфозасына (умарта кортлары һәм ефәк күбәләкләре) караган беренче фәнни хезмәтләре дөнья күрә. Соңыннан Э. үсешенә К.Линней (Швеция), француз натуралистлары Р.А.Реомюр һәм Ж.А.Фабр; Россия галимнәре П.С.Паллас, Э.К.Брандт, Ф.П.Кеппен, И.А.Порчинский, Н.А.Холодковский, А.П.Семёнов-Тян-Шанский, Г.Г.Якобсон, В.Л.Бианки һ.б.; Советлар Союзында — Е.Н.Павловский, В.Н.Беклемишев, Н.М.Кулагин, М.Н.Римский-Корсаков, Н.Н.Богданов-Катьков, Г.Я.Бей-Биенко, М.С.Гиляров һ.б. зур өлеш кертәләр.

Казанда энтомологик тикшеренүләр Казан ун-ты ачылганнан соң башланып китә. Профессорлар К.Ф.Фукс һәм А.М.Бутлеров, ун-тның беренче студенты С.Т.Аксаков бөҗәкләрне, нигездә, күбәләкләрне коллекцияләр. Аксаков «Күбәләкләр җыю» («Собирание бабочек», 1857) хикәясен бастыра, ул исә Россия күбәләкләре турында беренче популяр хезмәт була. Бутлеров Казан губернасы терр-ясендә яшәүче тәңкәканатлыларга, аерым алганда, бал кортларына багышланган хезмәтләр циклы чыгара. Аның хезмәтләре Россиядә умартачылыкның фәнни нигездә үсүенә ярдәм итә. Казанда Э. үсешенә проф. Э.А.*Эверсман* зур өлеш кертә: ул күбәләкләр, турыканатлылар һ.б. бөҗәкләрнең яңа төрләрен тасвирлый. Идел-Урал төбәге бөҗәкләренең фаунасы һәм экологиясе буенча җыентыклар эшли. 1862 елда Н.П.*Вагнер* тарафыннан икеканатлы бөҗәкләрдә педогенез (личинка аркылы үрчү) күренеше ачыклана. 1880 елларда Н.М.Мельников Казан ун-ты Табигыятьчеләр җәмгыятенең Казан губернасы терр-ясендә очраучы зарарлы бөҗәкләрне өйрәнүче һәм аларга каршы көрәш б-н шөгыльләнүче энтомологик комиссиясен җитәкли. М.Д.*Рузский* а.х., мед., вет. Э.сенең гомуми мәсьәләләрен өйрәнә, Россиядә беренче булып кырмыскалар фаунасын тикшерә; «Россия кырмыскалары» («Муравьи России», 1–2 кис., 1905–07) монографиясе авторы, Россия мирмекологлар мәктәбен нигезләүчеләрнең берсе.

1920 елларда урман Э.се (Н.В.Шмелёв, Н.А.Лисов), умартачылык (С.В.Жданов) үсеш алалар. Соңрак СССР ФА Казан ф-лының Биол. ин-тында туфрак бөҗәкләре фаунасы (М.М.Алейникова, Н.М.Утробина, Т.И.Артемьева), Казан ун-тында гөмбә таркатучы бөҗәкләр (Ә.Б.Халидов) буенча тикшеренүләр үткәрелә башлый. 1940 еллардан галимнәр паразит яшәү рәвеше алып баручы бөҗәкләргә: канәкчеч икеканатлылар (Н.И.Волкова), борчалар (И.В.Назарова), кошлар эктопаразитлары (В.И.Борисова, В.А.Бойко) һ.б.га зур игътибар бирәләр. Үлән капламындагы бөҗәкләрне тикшерү б-н О.С.Муравицкий, Е.М.Веселова, С.Н.Шәфигуллина шөгыльләнә. Тәңкәканатлыларны (С.Г.Гордиенко, Н.Г.Петров, Н.В.Шулаев), коңгызларны (Р.А.Суходольская, В.В.Леонтьев, Н.В.Шулаев) һ.б.ны өйрәнү дәвам итә. Татарстанда гомуми Э. — Казан ун-тында, а.х. Э.се — Казан аграр ун-тында, Татарстан үсемлекләрне саклау станциясендә, урман Э.се — Татарстан урман тәҗрибә станциясендә, вет. Э.се Казан вет. медицинасы академиясендә өйрәнелә. 1973 тән Бөтенсоюз (хәзер Рус) энтомология җәмгыятенең Казан бүлеге эшли (беренче рәисе — М.М.Алейникова, 1988 дән — Т.И.Артемьева, 2005 тән — Н.В.Шулаев).

*Әд.:* Т ы щ е н к о В.П. Основы физиологии насекомых: В 2 т. Л., 1976–77; Б е й - Б и е н к о Г.Я. Общая энтомология. М., 1980; Руководство по физиологии органов чувств насекомых. М., 1983; Р о с с Г., Р о с с Ч., Р о с с Д. Энтомология. М., 1985; К л ю г е Н.Ю. Современная систематика насекомых. СПб., 2000. Ч. 1.

*Н.В.Шулаев.*

**ЭНЦЕФАЛИ́Т**, вируслы (грек. enkephalos — баш мие; encephalitis acarina — талпан энцефалиты), РФдә, ш.и. Татарстанда таралган язгы-җәйге, табигый чыганаклы, трансмиссив инфекция. Авыруга халыкның яшь буенча барлык төркемнәре дә бирешүчән. Э. үзәк нерв системасы зарарлану б-н характерлана. Авыруны китереп чыгаручы РНКлы вирус арбовируслар төркеменә карый, 50°С та 10–20 минуттан үлә, дезинфекция чаралырына (хлорлы известь, хлорамин, лизол) бирешүчән. Вирусны туплаучы һәм күчерүчеләр — иксод талпаннары. Табигатьтә авыру тудыручының сакланышы талпаннар б-н тукланучы кыргый табигать вәкилләре: кимерүчеләргә (кыр тычканнары, тычканнар, бурындыклар) һәм кошлар (миләш чыпчыклары, купшыллар, кызылтүшләр) бәйле. Инфекция кешегә алиментар юл б-н дә күчәргә мөмкин (кайнатылмаган кәҗә яки сыер сөте аркылы). Инкубация чоры 3 көннән 20 көнгә кадәр. Вирус организмда кан һәм лимфа системасы аша һәм нейроген юл б-н тарала, нерв системасы күзәнәкләрендә үрчи һәм үзәк нерв системасына эләккән очракта диффузияле менингоэнцефалит китереп чыгара. Клиник картинасы күптөрле: а) еш кына кискен; кайвакыт авыру хроник формага күчә; б) инаппарат (симптомсыз), ачык билгеләре булмаган, бизгәкле, менингеаль; в) чыганаклы (паралитик) форма, ш.у. микст-инфекция. Вирус, авыруның хроник төренең сәбәбе булып, организмда гомер буе саклырга мөмкин. Э. кичергәннән соң авыруда ныклы иммунитет барлыкка килә. Авыруны кисәтү специфик (вакциналау) һәм специфик булмаган ысул б-н алып барыла.

1950 еллардан башлап талпан Э.ы проблемалары Казан эпидемиол. һәм микробиол. фәнни-тикшеренү ин-тының табигый чыганаклы инфекцияләр лаб-ясе хезмәткәрләре тарафыннан өйрәнелә: ТРда талпан Э.ының таралу учагы билгеләнә; паразитларның экологик яктан бер-берләренә якын төрләре арасындагы кискен каршылык ачыклана; авыруны кисәтү чаралары тәкъдим ителә (В.А.Бойко, Г.Х.Гыйльманова, В.Г.Ивлиев, Ю.П.Коваленко, Т.А.Башкирёв, 1970 еллар). 2010 елларга кадәр ТРда талпан Э.ы б-н авыру дәрәҗәсе югары була, шуннан соңгы елларда авырып китү очраклары кимүгә бара.

*Әд.:* Г и л ь м а н о в а Г.Х. Эпидемиологические и вирусологические материалы по характеристике очагов клещевого энцефалита в лесостепной зоне переносчиком Ixodes persulcatus: Дис. ... К., 1965; З а к и р о в а С.Ф. Реакция преципитации в исследованиях при клещевом энцефалите: Дис. ... К., 1966; Ш у в а л о в а Е.П. Инфекционные болезни. М., 1977.

*В.Х.Фазылов.*

**ЭНЦИКЛОПЕ́ДИЯ** (латин. — encyclopaedia, грек. enkyklios paideia — барлык белемнәргә өйрәтү), барлык белем өлкәләренә (универсаль Э.ләр) яки аерым белемнәргә (тармак Э.ләре) һәм гамәли эшчәнлеккә караган иң төп мәгълүматларны эченә алган фәнни яки фәнни-популяр белешмәлек. Э.дә кеше һәм ул яшәгән табигый тирәлек турында иң мөһим белемнәр тупланган. Э.ләр шул чорның фән һәм мәдәният үсеше дәрәҗәсен чагылдырып кына калмыйлар, ә бәлки үзләрен барлыкка китергән страт (сыйныф) яки халык мәнфәгатьләренә җавап бирүче идеологик һәм мәдәни рухны да алга сөрәләр. Беренче Э.ләр борынгы дөньяда: Кытайда, Мисырда, Грециядә, Рим империясендә һ.б.да барлыкка килә. Татар Э.сенең тамырлары Мәхмүд Кашгаринең «Диване лөгать әт-төрк» (1072–74) сүзлеге, «*Кодекс Куманикус*» («Команнар мәҗмугасы») кебек борынгы төрки язма ядкәрләренә, ш.у. урта гасырлар гарәп-фарсы традицияләренә (әл-Харәзми, әл-Фәраби, әл-Гарнати, әл-Мәсгуди һ.б.) барып тоташа. Беренче төрки-татар белешмәлек үрнәкләре 17 йөздән билгеле — Кадыйргали бәкнең «Җамигъ әт-тәварих» («Елъязмалар җыентыгы», 1602) тарихи хезмәте, авторы билгесез «Дәфтәре Чыңгызнамә», Хисаметдин әл-Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә»; 17–19 йөзләрдә татарлар арасында ыру, нәсел һәм гаиләләрнең *шәҗәрәсен* төзү киң тарала.

19 йөзнең 2 нче яртысында – 20 йөз башында, татар җәмгыятендә буржуаз мөнәсәбәтләр интенсив үсеш кичергән, этник үзаң уянган һәм милли историография формалашкан чорда, энциклопедик һәм фәнни-белешмәлек характерындагы хезмәтләр пәйда була: Ш.*Мәрҗанинең* «Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» (1838–89, 1–6 т., хәзергәчә кулъязма хәлендә), «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (1–2 кис., 1885, 1900); Р.*Фәхретдиннең* «Асар» (1–2 т., Оренбург, 1900–08; тулысынча 1–4 т., Казан, 2006–10), «Казан ханнары», «Алтын Урда




Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының энциклопедия басмалары.

ханнары»; К.*Бикколовның* «Татар ханнары» һ.б. Аларда татар халкының тарихы, мәдәнияте, мәгарифе, дини инанулары, гореф-гадәтләре, йолалары һәм мәшһүр затлары турында шактый мәгълүмат гомумиләштерелә һәм системага салына. Шул чорда практик-белешмәлек рәвешендә эшләнгән басма татар *календарьлары* дөнья күрә.

1920 елда Татарстан АССР төзелү б-н бәйле рәвештә респ-када татар халкын өйрәнү гыйлеме көчле үсеш кичерә: күпсанлы фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр арасында энциклопедик характердагы белешмәлек басмалар да була, ш.и. И.Рәмиевнең «Татар вакытлы матбугаты. Альбом (1905–1925)» (татар газета-журналлары, нәшриятлары, наширлар һәм мөхәррирләр турындагы мәгълүматлар); Ә.Максудиның «Фәнни камус» (аның тарафыннан тупланган 10 мең фәнни, иҗтимагый-сәяси термин һәм төшенчәдән барлыгы 2300 генә бастырыла) хезмәтләре.

Ләкин СССРда нэп чоры либерализмы озак дәвам итми. 1920 еллар ахыры – 1930 еллар башында Татарстанда татар дөньясын һәм туган төбәкне фәнни өйрәнү акрынлап сүрелә. Совет автономияләрендә Э.ләр рәвешендә белешмәлекләр төзү рәсми булмаган тыюга дучар була.

Милли-төбәк Э.ләре булдыру мәсьәләсенә татар җәмәгатьчелеге «Хрущёв җепшеклеге» елларында (1950 елларның 2 нче яртысы – 1960 еллар башы) кабат әйләнеп кайта. В 1957 дә күренекле татар язучысы һәм драматургы Әхмәт Фәйзи матбугатта «Татарча энциклопедик сүзлек кирәк» дигән мәкалә бастыра. 1930 елларга кадәр эшләгән Археол., тарих һәм этнография җәмгыятен торгызу омтылышы ясала, аны гамәлгә кую съезды уздырыла, һәм 1963 тә җәмгыять «Труды Общества истории, археологии и этнографии» басмасының 1 нче санын нәшер итә. Иҗтимагый хәрәкәт үз алдына куйган максатларның берсе милли-төбәк фәнни һәм фәнни-белешмәлек әдәбият бастырып чыгарудан гыйбарәт. Тиздән җәмгыятьнең эшчәнлеге, сәбәпләре рәсми рәвештә игълан ителмәстән, туктатыла. Шулай итеп, татар җәмәгатьчелегенең милли-төбәк Э.се булдыру башлангычы СССРдагы милли автономияләр халыклары вәкилләренең милли-төбәк Э.ләре эшләп бастыру өлкәсендәге фәнни-иҗади эшчәнлеген чикләүче чираттагы адм. киртәләргә килеп терәлә.

Андый хокук фәкать союздаш респ-каларга һәм Мәскәүдәге «Зур Совет энциклопедиясе» нәшриятына гына бирелә. Казан пед. ин-ты профессоры Р.Ш.*Таһиров* һәм аның фикердәшләре тарафыннан җыелган материалларга ул вакытта ихтыяҗ белдерелми. Соңрак аларның бер өлеше ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе ин-тына тапшырыла.

1980 еллардагы үзгәртеп корулар барышында, татар халкы Татарстанның дәүләт суверенитеты өчен көрәш алып барган һәм татар халкын өйрәнү яңа көч б-н үсеш алган чорда, Татарстан АССР МСның «Татар Совет Энциклопедиясен әзерләү һәм бастыру турында»гы карары (1989 ел, 6 сентябрь) нигезендә, Татар Совет Э.сенең Фәнни-оештыру советы (М.Х.*Хәсәнов* (рәис), В.Е.Алемасов һәм М.З.Зәкиев аның урынбасарлары; әгъзалары: Н.И.Бех, С.Г.Богатырёв, Е.В.Богачёв, Ю.М.Воронин, Э.М.Галиев, А.И.Коновалов, З.З.Сафин, Г.Җ.Сәхапов, М.М.Таишев, Ф.Г.Хәмидуллин, Р.Г.Юсупов һ.б., барлыгы 48 кеше) һәм Татар Совет Э.сенең Баш фәнни мөхәрририят коллегиясе (М.Х.Хәсәнов (рәис), М.З.Зәкиев һәм Ю.И.Смыков аның урынбасарлары, әгъзалары: Б.А.Арбузов, М.Г.Госманов, М.Ә.Илһамов, К.Ә.Вәлиев, М.И.Мәхмүтов, Р.З.Сәгъдиев, И.А.Тарчевский, П.А.Кирпичников, В.Н.Пудовик, Г.С.*Сабирҗанов*, И.Р.Таһиров, Ә.Р.Тенишев һ.б., барлыгы 43 кеше) төзелә.

1990 ның гыйнварында «Татар энциклопедиясе»н татар һәм рус телләрендә әзерләү һәм бастыру буенча фәнни-оештыру эшләрен координацияләү максатыннан СССР Фәннәр академиясе Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты каршында Татар Совет Э.се бүлеге булдырыла (мөдире — Ф.С.*Хәкимҗанов*). 1992 дән 1994 кә кадәр Г.С.Сабирҗанов җитәкчелегенә бүлек ТР ФА Президиумы каршында эшли. 1994 тә әлеге бүлек нигезендә ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-ты (җитәкчесе — ТР ФА Президенты М.Х.Хәсәнов; аның беренче урынбасары — Г.С.Сабирҗанов; 2014 нең декабреннән — ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-ты) оештырылганнан соң, «Татар энциклопедиясе»нең фәнни концепциясенә үзгәрешләр кертелә һәм аның Генераль лөгатьлеге киңәйтелә, рус һәм татар телләрендә Татар энциклопедия сүзлеге төзү буенча планлы эш башлана (к. таблицаны). ТР Президенты М.Ш.Шәймиевның «Татар энциклопедиясе» программасы турында» Указы һәм «Татар энциклопедиясе»нең баш мөхәррире турында Нигезләмә» (1997) басылып чыкканнан соң, рус һәм татар телләрендә күптомлы «Татар энциклопедиясе» төзүгә керешелә. 2014 тә «Татар энциклопедиясе»нең

*Таблица*

| Энциклопедияләр, сүзлекләр | Томнар | Еллар | Күләм | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | бит | мәкалә | илл. |
| Татарская энциклопедия | 1: А–В | 2002 | 672 | 3700 | 1300 |
| | 2: Г–Й | 2005 | 656 | 3150 | 1200 |
| | 3: К–Л | 2006 | 664 | 2930 | 1234 |
| | 4: М–П | 2008 | 768 | 3700 | 1100 |
| | 5: Р–Т | 2010 | 736 | 3484 | 1110 |
| | 6: У–Я | 2014 | 720 | 3664 | 1153 |
| Татар энциклопедиясе | 1: А–В | 2008 | 720 | 3860 | 1200 |
| | 2: Г–Й | 2010 | 656 | 3320 | 955 |
| | 3: К–Л | 2012 | 716 | 3190 | 1240 |
| | 4: М–П | 2014 | 632 | 2966 | 930 |
| | 5: Р–Та | 2016 | 728 | 2900 | 952 |
| | 6. 1 кис.: Тә–Ч | 2019 | 612 | 2820 | 990 |
| | 6. 2 кис.: Ш–Я | 2021 | 512 | 2115 | 422 |
| Татарский энциклопедический словарь | 1: А–Я | 1999 | 704 | 16000 | |
| Татар энциклопедия сүзлеге | 1: А–Я | 2002 | 830 | 17000 | |
| Иллюстрированная энциклопедия «Татарстан» | 1: А–Я | 2013 | 816 | 4070 | 3200 |
| Краткая иллюстрированная энциклопедия «Татарстан» | 1: А–Я | 2015 | 828 | 4100 | 3220 |
| Энциклопедический справочник для средств массовой информации «Республика Татарстан» | 1: А–Я | 2016 | 408 | 1870 | 920 |
| Иллюстрированная энциклопедия «Природа и природные ресурсы Республика Татарстан» | 1: А–Я | 2017 | 584 | 1975 | 928 |
| Краткая иллюстрированная энциклопедия «Татары Казахстана» | 1: А–Я | 2017 | 524 | 602 | 304 |
| Иллюстрированная энциклопедия «Населённые пункты Республики Татарстан» | 1: А–Б | 2018 | 712 | 1085 | 2600 |

рус телендәге 6 томлы, 2021 дә — татар телендәге 6 томлы (соңгы томы 2 кисәктә) басмаларын нәшер итү уңышлы тәмамлана (к. табл.).

Күптомлы «Татар энциклопедиясе»нең концептуаль нигезендә, кайда яшәүләренә карамастан, фән, мәгариф, спорт өлкәсендәге, иҗтимагый, сәяси, хәрби, дини, хуҗалык һ.б. эшчәнлегендәге казанышлары б-н танылган татар милләте вәкилләрен, ш.у., кайсы милләттән булуларына карамастан, Татарстанның атаклы кешеләрен Э.гә кертергә мөмкинлек бирүче «барысы да — татарлар һәм Татарстан турында» принцибы ята. «Татар энциклопедиясе»нең 6 томында якынча 21 мең «кара сүз», ш.и. шәхесләргә багышланган 9 меңләп мәкалә бар. «Татар энциклопедиясе»ндә Россия Федерациясе, якын һәм ерак чит илләрнең татар диаспорасы вәкилләре лаеклы чагылыш таба.

Бер үк вакытта тармак Э.ләре дөнья күрә: 2013 тә Казандагы 27 нче Бөтендөнья җәйге студентлар уеннары — «Универсиада-2013» уңаеннан иллюстрацияле «Татарстан» Э. се, 2015 тә спортның су төрләре буенча дөнья чемпионатына туры китереп, иллюстрацияле кыскача «Татарстан» Э. се, 2016 да гаммави мәгълүмат чаралары өчен «Татарстан Республикасы» энциклопедик белешмәлеге, 2017 дә рус телендә «Татарстан Республикасының табигате һәм табигый ресурслары» («Природа и природные ресурсы Республики Татарстан», к. таблицаны) Э.се, ш.у. ин-т коллективы катнашында татар телендә «Габдулла Тукай» Э.се (2016) эшләнә.

Хәзерге вакытта Татарстанда тармак Э.ләре: «Татарстан Республикасының торак пунктлары» («Населённые пункты Республики Татарстан», 3 томда; 1нче томы 2018дә дөнья күрә), «Казан» («Казань»), «Татарстан халыклары» («Народы Татарстана») һ.б. Э.ләр әзерләү эшләре бара.

Күп томлы Татар Э.се басылып чыгу Татарстанда Актаныш, Апас, Әлмәт, Балтач, Буа, Зәй, Спас һ.б. районнарның муниципаль Э.ләре һәм белешмәлекләре, ш.у. Россия Федерациясе субъектларының кайберләрендә («Сембер-Ульянов төбәге татарлары» — «Татары Симбирско-Ульяновского края», 2016) һәм БДБ илләрендә («Казакъстан татарлары» — «Татары Казахстана» иллюстрацияле энциклопедик белешмәлеге (2016), «Казакъстан татарлары» — «Татары Казахстана» иллюстрацияле кыскача Э.се (2017) татар диаспораларына багышланган энциклопедик сүзлек-белешмәлекләр дөнья күрүгә этәргеч бирә. Милли энциклопедик басмалар әзерләп нәшер итүдә БДБ илләре арасында Казакъстан Респ-касының татар диаспорасы вәкилләре актив эшчәнлек алып бара («Казакъстан татарлары: энциклопедик сүзлек» — «Татары Казахстана: энциклопедический словарь», Алма-Ата, 2011, 2015; Астана, 2014).

*Әд.:* Я р у л л и н а А.Г., Х ә м и д у л л и н Л.Х. Татар энциклопедиясенең нигез ташлары // Фән һәм тел. 2005. №1; Гыйлем хәзинәсе. Казан, 2009; Ш ә й д у л л и н Р.В., В ә л и е в Р.М. XIX гасырның икенче яртысында — XXI гасыр башында Россиядә татар милли энциклопедистикасының барлыкка килүе һәм үсеше // Фәнни Татарстан. 2014. № 4; С а б и р з я н о в Г.С. Универсальный свод знаний // Наука и общество. 1995. №2; Региональные энциклопедии: проблемы общего и особенного в истории и культуре народов Среднего Поволжья и Приуралья. Казань, 2007; Исторический опыт, актуальные проблемы развития российской региональной энциклопедистики: сборник статей Всероссийской научно-практической конференции (г.Уфа, 27–28 сентября 2012). Уфа, 2012; Российская многонациональная энциклопедистика: история и современность: Сб. науч. работ. К., 2017; С а б и р з я н о в Г.С. Энциклопедистика в Татарстане и некоторые вопросы историографии народов Поволжья и Южного Приуралья // Українська енциклопедистика: матеріали Другої міжнародної наукової конференції (м. Київ, 17 червня 2011 року). Киев, 2014; Ш а й д у л л и н Р.В. Татарская энциклопедистика: настоящее и будущее // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. 2013. № 4 (2); Технологическая концепция онлайн-энциклопедии TATARICA 2.0. К., 2018.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ЭҢЕ́Р ҮЛӘНЕ́**, гөрнәк (Rorippa), әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 70 төре билгеле, башлыча Төньяк ярымшарның уртача поясында очрыйлар. ТР терр-ясендә 7 төре бар: Исландия яки саз Э.ү. (R. palustris), урман Э.ү. (R. sylvestris), ике яклап үткен Э.ү. (R. anceps), кыска орлыклы Э.ү. (R. brachycarpa), җир-су Э.ү. (R. amphibia), Австрия Э.ү. (R. austriaca), керәнсыман Э.ү. (R. armoracioides). Респ-каның барлык терр-ясендә таралганнар. Елга ярлары буенда, дымлы һәм сазлыклы урыннарда, су баса торган болыннарда үсәләр. 15–100 *см* биеклектәге үсемлекләр. Сабагы туры, төкчәле. Суга күмелгән яфраклары җепсыман сегментларга аерылган. Чәчәкләре сары төстә, тыгыз чукка җыйналган. Җимеше — кузак. Май-сентябрьдә чәчәк аталар. Җир өсте өлешләрендә флавоноид, сапониннар бар. Фунгицид үзлекләргә ия. Җир-су Э.ү. — терлек азыгы.

**ЭПЕНТЕ́ЗА** (грек. epénthesis — өстәү, ялгау), сүзнең башлангыч формасында күзәтелмәгән өстәмә аваз барлыкка килү. Э., гадәттә, татар телендә күзәтелмәгән авазлар тезмәсе хас булган алынма сүзләрдә барлыкка килә. Татар әдәби телендә, аеруча сүз башында тартыклар янәшә килә алмый, шуңа күрә башка телдән кергән сүзләрне әйткәндә, тартыклар арасына сузык авазлар өстәлә (еш кына сонор [р] һәм [л] тартыклары алдыннан [ы] яки [е] авазлары): б(ы)ронза, дуб(е)ль, пар(ы)к, бан(ы)к, цир(ы)к.

Татар әдәби теленә совет чорына кадәр кергән сүзләрдә Э. орфографиядә дә чагылыш таба: борыс, караватं, келәт, келәшчә, сумала.

Диалектларда һәм гади сөйләмдә тартык аваз өстәлеп ясалган саф татар сүзләре дә кулланылган очраклар бар: яң(г)а, себер(т)ке.

*Әд.:* Татар грамматикасы. К., 1998. Т. 1; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998.

*Р.Ә.Закиров.*

**ЭПИГРА́ММА** (грек. epígramma — язма), сатирик поэзиянең бер төре, теге яки бу шәхестән ачу б-н көлеп язылган кыска күләмле шигырь. Борынгы Грециядә Э. дип гыйбадәтханәдәге, сын нигезендәге, савыттагы һ.б.ш. шигъри (сирәк проза б-н язылган) язманы атаганнар, соңрак антик әдәбиятта — теге яки бу шәхескә мөрәҗәгать итү, үгет-нәсыйхәт әйтү, теләк теләү, мактау, шелтәләү һ.б. рәвешен алган лирик поэзиянең кече жанры. Татар әдәбиятында, аеруча сәяси Э.лар Г.Тукай, Ш.Бабич, соңрак Ә.Исхак, З.Мансур, Г.Афзал, Ш.Галиев, М.Галиев, Р.Зәйдулла, Ф.Баттал иҗатларында урын ала. 20 йөз ахырында Э.ның мәхәббәт, табын арты һ.б. тематик төрләре барлыкка килә.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*А.А.Шәмсутова.*

**ЭПИГРА́ФИКА** (грек. epigraphḗ — өстендәге язу), таш плитәләрдә, кыяларда, тимер, агач, сөяк, пыяла һәм керәч әйберләрдә һәм чүлмәк ватыкларында сакланып калган борынгы һәм урта гасырлардагы язмаларны өйрәнүче тарих һәм филол. фәннәре тармагы. Э. ядкәрләре текстлары — борынгы һәм урта гасырлар дин, сәясәт, социаль, икътисад тарихы чыганакларыннан берсе. *Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләренең* В.Томсен тарафыннан ачыклануы (1893), В.В.Радлов тарафыннан укылуы һәм тәрҗемә ителүе (1894) төрки Э. ядкәрләрен тикшерү эшенә нигез сала. Татарстанда Э. фәнни юнәлеш буларак 19 йөздә Ш.Мәрҗани, К.Г.Насыйри, Х.Фәезханов, И.Н.Березин, Н.Ф.Катанов, Г.Н.Әхмәров хезмәтләрендә барлыкка килә. Соңрак С.Е.Малов, Н.Ф.Калинин, Г.Рәхим, Л.Җ.Җәләй, Һ.В.Йосыпов, Ф.С.Хәкимҗанов, Ә.Г.Мөхәммәдиев, Ж.Г.Мөхәммәтшин һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә үсеш ала. Ш.у.к. *Борынгы төрки рун язуы.*

*Әд.:* М ө х ә м м ә д и е в Ә. Һуннар һәм Туран язмалары. К., 2000; Ю с у п о в Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.-Л., 1960; Х а -



Кабер ташлары. 1. 14 йөз башы. Болгар тарих-архитектура тыюлыгы музее; 2. 16 йөз. Биектау районының Туктамыш авылы; 3. 16 йөз. Яшел Үзән районының Мулла Иле авылы; 4. 19 йөз. Чистай районының Наратъелга авылы.

к и м з я н о в Ф.С. Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык. М., 1987; М у х а м е т ш и н Д.Г. Татарские эпиграфические памятники: Региональные особенности и этнокультурные варианты. К., 2008.

**ЭПИГРА́ФИКА ЯДКӘРЛӘРЕ́** (болгар-татар эпиграфика ядкәрләре), 13–20 йөзләрдә болгарлар һәм Идел-Урал буе татарлары яшәгән төбәкләрдәге таш плитәләрдә сакланган борынгы язмалар. Кабер ташларына язылган эпиграфика ядкәрләре аеруча өйрәнелгән дип санала. Каберләр өстенә таш яки агач һәйкәлләр куяу б-н бәйле мәҗүсилек традициясе (к. *Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләре*) татар халкында алга таба да саклана. Фәнни яктан теркәлгән иң борынгы ядкәр 1244 елга карый. Борынгы төрки (к. *Идел буе рун (чөй) язуы истәлекләре*) һәм ислам традицияләренә нигезләнгән кабер ташъязмалары 13 йөз ахырында киң таралыш ала. Урта Идел буендагы 92 торак пунктта 13 йөз ахыры — 14 йөз башына караган якынча 400 ядкәр табыла. Алар барысы да диярлек озынлык һәм киңлек чагыштырмасы 4:1 нисбтендәге турыпочмаклы стела рәвешендә була. Кагыйдә буларак, язмалар кабер ташларының өслегенә чокып язылган, шулай да борынгы Болгар шәһәре терр-ясендә күпчелек ядкәрләрнең язмалары ташларның ян-якларында һәм арткы ягында да очрый. Текстлар, гадәттә, Коръән аятьләрен, җирләнгән кешенең исемен, нәселен, үлем датасын һәм үлгән кешегә багышланган яхшы теләкләрне үз эченә ала.

Болгар каберлекләрендә язусыз, ш.у. төрле билгеләр куелган яки бөтенләй эшкәртелмәгән ташлар да урнаштырылуы билгеле. Күпчелек стелалар үсемлек һәм геом. орнаментлар б-н бизәлгән. Алар, гадәттә, тимпанда һәм кайма буйлап, сирәк кенә ташның арткы ягында урнашкан. Болгар, Кирмән-Җүкәтау, Көнчыгыш һәм Төньяк төбәкләренә караган ядкәрләрдәге текстларның сәнгати бизәлеше һәм структурасында җирле һөнәрче осталарның традицияләре б-н бәйле аермалар табыла.

Ядкәрләрдәге текстлар куфи, сөлес, нәсех (к. *Гарәп язуы үрнәкләре*), батынкы һәм рельефлы шрифт кебек төрле стильләр б-н бизәлә. Язу өчен гадирәк дип табылган шрифт болгар куфие исемен йөртә. Тарихчы Н.Ф.Калинин һәм тюрколог Һ.В.Йосыпов ташъязмаларның ике стилен аерып карыйлар: 1) гарәп һәм төрки телләрдә рельефлы сөлес шрифты б-н; 2) болгар телендәге текстны куфи шрифты б-н башкару. Иң борынгылары гарәп телендә һәм *Идел буе төрки телендә* язылган. 13 йөздә алар кабер ташъязмаларының 70% тан артыгын тәшкил итә. Ядкәрләрнең бер өлеше болгарларның сакланып калган ыру-кабилә шивәләрен чагылдыра. Күпчелек тикшеренүчеләр (Н.Ф.Калинин, Һ.В.Йосыпов, Л.Җ.Җәләй, М.З.Зәкиев, Ф.С.Хәкимҗанов) фикеренчә, эпиграфика ядкәрләренең теле бертөрле түгел һәм Идел буе татарлары теленә якын.

14 йөз уртасында Алтын Урда хакимияте кризис кичерү һәм таркала башлау б-н бәйле рәвештә ядкәрләрнең саны кими башлый, бизәлешләренең сәнгати дәрәҗәсе төшә. 14 йөз ахырына — 15 йөз башына караган өч ядкәр билгеле. Ядкәрләр татар телендә язылган (гарәп телендә эшләнгән Коръән формуласыннан тыш). 15 йөз башында — Казан ханлыгы формалашу чорында кабер ташлары эшләү традициясе яңа нигездә торгызыла. Сакланып калган 200 дән артык кабер ташының күпчелеге 16 йөз башында куелган. Ядкәрләр хронолик яктан һәм эшләнешләре б-н берничә төргә бүленә: 1) очлы яки турыпочмаклы башлы һәм өске өлешендә алты почмаклы йолдыздан гыйбарәт булган; 2) ярымтүгәрәк башлы һәм бүлемтекле орнамент яки үрелмә рәвешендәге каймалы; 3) очлы яки киль рәвешендәге башлы, уксыман а́ркалы; 4) очлы башлы һәм буеннан-буена орнаментлы (йөзем тәлгәше) ядкәрләр; өске өлешендә — лалә рәвешендәге бизәк; 5) нәфис итеп бизәлгән һәм арткы, ян якларында язмалары булган ташлар.

16 йөзнең 2 нче чирегендә ташларның өске өлешен зур үсемлек орнаментлары б-н бизәү, ян-якларында язулар һәм арткы ягында кабер ташы куючының кем булуын теркәү формасында эшләү гадәткә керә. Кабер ташлары язулары татар һәм гарәп телләрендә була. Казан ханлыгы җимерелү Э.я. әзерләүне берникадәр вакытка туктатарлый. 16 йөзнең икенче яртысындагы — 17 йөздәге 50 гә якын ядкәр сакланган (башлыча, Касыйм шәһәрендә). Нигездә, алар Казан кабер ташлары б-н охшаш, әмма аеруча купшы бизәлгән, Коръән формулалары, текстта кардәшлек титуллары һәм терминнары күп булу б-н аерылып тора.

18 йөз уртасыннан Э.я. әзерләү традициясе кабат торгызыла. 18 йөзнең 2 нче яртысына — 20 йөз башына нисбәтле язулы кабер ташлары күпчелек очракта татар халкы тупланып яшәгән терр-ядәге татар торак пунктларында еш очрый.

*Әд.:* Ф е й з х а н о в Х. Три надгробных болгарских надписи // Изв. Имп. рус. археол. об-ва. 1863. Т. 4; Ю с у п о в Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.-Л., 1960; Х а к и м з я н о в Ф.С. Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык. М., 1987; З а к и е в М.З., К у з ь м и н - Ю м а н а д и Я.Ф. Волжские булгары и их потомки. К., 1993; М у х а м е т ш и н Д.Г. Татарские эпиграфические памятники: Региональные особенности и этнокультурные варианты. К., 2008.

*Җ.Г.Мөхәммәтшин.*

**ЭПИДЕМИОЛО́ГИЯ** (грек. epí — өстә,өске, dḗmos — халык, кешеләр һәм ...*логия*), медицинаның кешелек җәмгыятендә йогышлы авыруларның барлыкка килүен һәм таралу закончалыкларын өйрәнә торган өлкәсе, аларны кисәтү һәм юк итү ысулларын эшли. Фәнни дисциплина буларак, Э. фундаменталь фәннәр б-н тыгыз бәйләнгән, тасвирлау-аналитик һәм конструктив өлешләргә бүлеп карала.

19 йөздә Россиядә эпидемияләргә каршы көрәшү максатыннан фәнни-гамәли учреждениеләр, чик буйларында даими «карантиннар», дезинфекция станцияләре (1874, Одесса ш.; 1879, Петербург) булдырыла. И.И.Мечников (иммунитет турындагы тәгълимат авторы) һәм Н.Ф.Гамалея тырышлыгы б-н Россиядә беренче земство бактериол. станциясе (Одесса ш., 1886) барлыкка килә. 1880–90 елларда Мәскәүдә, Харьков, Екатеринослав (Днепропетровск), Чернигов, Киев, Одесса шәһәрләрендә бактериол. ин-тлары ачыла. Мәскәүдә, Петербург, Харьков, Самара һ.б. шәһәрләрдә, 1900 да ш.у. Казанда «Пастер станцияләре», Батумида беренче малярия станциясе оештырыла (1913).

19–20 йөзләр чигендә түләмәне китереп чыгаручы бацилла һәм туберкулёзны китереп чыгаручы микобактерияләр билгеле була; түләмә вакцинасын алу ысулы эшләнә (Л.С.Ценковский); котыру авыруына каршы ясала торган прививкаларның зарарсызлыгы исбатлана; холера (ваба), чума һәм тимгелле тифка (Н.Ф.Гамалея) каршы көрәш чаралары системасы тәкъдим ителә, йогышлы сары авыруы турындагы тәгълиматка нигез салына (С.П.Боткин). 1979 да дөньяда чәчәк авыруы юкка чыгарыла. 20 йөзнең 2 нче яртысында хәрби Э., эксперименталь Э., стерилизация б-н бергә дезинфекция эше, паразитар авырулар Э.се, аеруча куркыныч инфекцияләр Э.се, зооноз инфекцияләр Э.се мөстәкыйль фәнни тармак булып аерылып чыга.

ТР терр-ясендә фәнни Э. Казан Эпидемиол. һәм микробиол. ин-тында (1925 кә кадәр Казан ун-ты составындагы Бактериол. ин-ты) 1900 еллардан үсеш ала. Э. курсы Казан. мед. ин-тында 1932 дә оештырыла (лекцияләрне проф. Б.А.Вольтер укый). 1938 дә Э. каф. оештырыла (мөдирләре В.И.Попов, А.Э.*Озол*, В.И.*Качурец*, И.З.*Мөхетдинов*, М.Ш.*Шәфиев*, Н.М.Хәкимов, И.Г.Закиров, И.К.Хәсәнова, 2014 тән — Г.Р.Хәсәнова). Кафедрада корсак тифы, иерсиниоз, дифтерия һәм башка эчәк инфекцияләре тикшерелә; организмның иммунологик реактивлыгына яшәү тирәлегенең тәэсире өйрәнелә; бу авыруларны дәвалау һәм кисәтү ысуллары эшләнә. Э. һәм дезинфектология каф. Казан. мед. академиясендә 1956 да нигезләнә (оештыручысы һәм мөдире Н.Н.Спасский, мөдирләр — Ә.Г.Хисаметдинов, В.Е.Григорьев, 2008 дән — В.А.Трифонов). Кафедраның төп фәнни тематикасы — вируслы гепатит, туберкулёз авыруларына эпидемиол. күзәтчелекне гамәлгә кертү һәм эшнең нәтиҗәлелеген бәяләү, ТР дагы табигый чыганакларның эпидемиол. халәтен өйрәнү.

Озак вакытлар дәвамында дифтерия иң куркыныч инфекцияләрнең берсе булып кала килә (100 мең кешегә 100 очрак, үлем — 5–10%). 20 йөз уртасында иммунопрофилактикага бәйле рәвештә, балаларның полиомиелит, дифтерия һәм кызамык б-н авыру очраклары кискен кими. Полиомиелитка каршы көрәштә (1960 еллардан) бу авыруның таралышын контрольгә алу мөмкинлеге биргән Сэбин вакцинасы кулланыла.

20 йөз ахырында, наркомания һәм инфекциянең җенси юл б-н күчүе киң таралыш алу сәбәпле, В гепатиты (шприц аша күчүе) эпидемик төс ала. Профилактик прививкалар календарена кертелгән (1997 дән) В гепатитына каршы вакцинацияләү авыруның сизелерлек кимүенә булышлык итә (к. *Вируслы гепатитлар*).

Казан эпидемиологлары тарафыннан чәчәк авыруын кисәтү һәм бетерү (И.З.Мөхетдинов), эчәк инфекцияләре (И.З.Мөхетди-

нов, Д.А.Якобсон), бавыр синдромлы геморрагик бизгәк (Т.А.Башкирёв) б-н көрәш ысуллары эшләнә; эпидемиол. дизентерия (Н.Н.Спасский, А.И.Сорокин), вируслы гепатитлар (Д.К.Бәширова, И.М.Хәертинова, В.А.Трифонов, Э.Х.Мамкеев), стрепто- һәм стафилококклы инфекцияләрне кисәтү (В.Е.Григорьев) мәсьәләләре өйрәнелә, яңа вакциналарның иммунологик үзлекләре, гамма-нурланышның һәм пестицидларның организмның иммунологик реактивлыгына тәэсире тикшерелә (М.Ш.Шәфиев). Р.К.Мирсаяпова («АКДС вакцинасы белән иммуниацияләү барышында кискен респиратор вируслы инфекцияләрнең балаларның специфик иммунитеты халәтенә тәэсире» — «Влияние острых респираторных вирусных инфекций на состояние специфического иммунитета у детей в процессе иммунизации АКДС вакциной», 1975), Ф.Ф.Садыйков («Прививкаланган балаларда кызамыкның эпидемиологик һәм иммунологик үзенчәлекләре» — «Эпидемиологические и иммунологические особенности кори у привитых детей», 1986), В.Е.Григорьев («Төрле юнәлешле стационарларда хастаханә инфекцияләренә каршы көрәш чараларын оештыру һәм камилләштерү юллары» — «Организация и пути совершенствования мероприятий по борьбе с внутрибольничными инфекциями в стационарах различного профиля», 1992), Э.Х.Мамкеев («Фертиль яшьтәгеләр, авырлы хатыннар һәм яңа туган балаларда В гепатиты вирусының эпидемиологик үзенчәлекләре» — «Эпидемиологические особенности вирусного гепатита В у лиц фертильного возраста, беременных, новорождённых детей», 1994), М.Ш.Шәфиева, И.К.Хәсәнова, Р.Ш.Якупов («Гельминтозлар эпидемиологиясе һәм профилактикасы» — «Эпидемиология и профилактика гельминтозов», 2003) тикшеренүләре Э.нең алга таба үсешен тәэмин итә. 2000 еллардан Э. психик авырулар, атеросклероз, инсульт, яман шеш, йөрәк-кан тамырлары авырулары Э.н өйрәнү буенча тикшеренүләр алып барыла (1959 дан Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы программаларына кертелә).

*Әд.:* Заболотный Д.К. Основы эпидемиологии. М.-Л., 1927; Озол А.Э. Сравнительная оценка метода толстого мазка и биологической пробы в практике лабораторной диагностики туберкулёза // Проблемы туберкулёза. 1937. № 2; Шляхтенко Л.И. Новые направления в современной эпидемиологии. СПб., 1998; Покровский В.И., Онищенко Г.Г., Черкасский Б.Л. Эволюция инфекционных болезней в России в XX веке. М., 2003; Брико Н.И., Зуева Л.П. и др. Эпидемиология. В 2-х т. М., 2013; Госпитальная эпидемиология: руководство к практическим занятиям. М., 2015; Общая эпидемиология с основами доказательной медицины. М., 2018.

*Э.Х.Мамкеев, Ф.Ф.Нуриева.*

**Э́ПИК ФО́РМУЛАЛАР**, халык әкиятләре, эпик хикәяләр, дастаннар, бәетләр һ.б. фольклор әсәрләре башында, ахырында, сирәк кенә хикәяләү барышында очраучы тотрыклы сүзтезмәләр. Тасвирлана торган вакыйгаларның борынгылыгын һәм (яисә) дөреслеген ассызыклыйлар: «Борын-борын заманда торганнар бер карт белән бер карчык». Еш кына бәетләрнең башлам һәм йомгак өлеше ролен башкаралар: «Бисмилләһи вә билләһи, җитте Корбан гаете. Без язабыз, сез укырсыз лашманчылар бәетен». Э.ф. вакыйгаларны тасвирлаганда да кулланылырга мөмкин: «Бик озак вакытлар йөргәннең соңында...», «Байтак юллар киткәч, бик калын урманга җиткәч...».

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Типологические исследования по фольклору. М., 1975; Фольклор. Поэтическая система. М., 1977.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЭПИСТОЛЯ́Р ӘДӘБИЯ́Т**, (грек. epistolḗ — язу), 1) басылган шәхси хатлар; 2) хат рәвешендә язылган тезмә һәм чәчмә әсәрләр. Фәнни, публицистик Э.ә. бар. Эпистоляр матур әдәбият аеруча киң таралган; төп формалары — шигъри хат, хатлар рәвешендә язылган роман. Татар әдәбиятында Э.ә. элементлары «Идегәй» дастанында, Г.Кандалый, Г.Утыз Имәни һ.б. әсәрләрендә очрый. Татар әдәбиятында мөстәкыйль жанр буларак Э.ә. 20 йөз башында барлыкка килә: Г.Тукайның «Ана мәктүбләре», Ш.Камалның «Сердәшләр» әсәрләре. Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар», Һ.Такташның «Киләчәккә хатлар», А.Гыйләҗевнең «Кызлар хатлары», С.Батталның «Батый ханга ачык хат» һ.б әсәрләре яңа заман татар әдәбиятындагы эпистоляр жанр үрнәкләре булып торалар.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*А.А.Шәмсутова.*

**ЭПИТА́ФИЯ** (грек. epitáphios — кабер ташына язылган), кабер ташындагы язма. Гадәттә Э. үлемнең котылгысызлыгы турында уйланулардан, мәрхүмнең исеме һәм кыскача тормышын тасвирлаудан, мәрхүмнең исәннәргә мөрәҗәгатеннән гыйбарәт. Баштарак ташка, мәрмәргә, металлга рун язуы б-н язганнар. Иң борынгы төрки Э.ләр 6–8 йөзләрдән билгеле. Себердә, Урта Азиядә (Кыргызстан), Монголиядә табылалар. Төркиләр тарафыннан ислам кабул ителгәч, Э.ләр гарәп язуы б-н языла башлый. Э. ядкәрләре Караханилар ханлыгы (12 йөз), Алтын Урда терр-ялрендә табылалар. Алтын Урда таркалгач, кабер ташларына язу сизелерлек кими. 15 йөз ахырыннан Казан, Кырым ханлыкларында, Шәйбанилар дәүләтендә чираттагы күтәрелеш кичерә. 1552 елда Казан ханлыгы яулангач, кабер ташларына язу кабат кими һәм 19 йөз ахырында гына яңадан үсеш ала. Э.ләрне өйрәнүгә Х.Фәезханов, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Рәхим, Ф.Хәкимҗанов һ.б. өлеш кертәләр.

*Әд.:* Әхмәтҗанов М. Ташбилгеләргә язылган татар әдәбияты үрнәкләре. К., 2011; Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.-Л., 1960; Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. М., 1978.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ЭПИФИ́ЛЛЮМ** (Epiphyllum), кактусчалар семьялыгыннан куакчыл үсемлекләр ыругы. Якынча 30 төре һәм 200 ләп гибрид формасы бар, культурада «филлокактус» (Phyllocactus) исеме б-н билгеле. Чыгышы — Мексика һәм Көньяк Америка. Сабагы түгәрәк, төбендә агаччыл, акрынлап читләре сирәк кенә тешле яки уемтылы өч кырлы яссы яфраксыман ботакка әверелә. Яфраклары кечкенә тәңкәчекләр булып редукцияләшкән. Чәчәкләре ак, аксыл сары төстә, берле, бүрәнкәсыман, озын чәчәк көпшәле, төнлә ачылалар. Чәчәк бөреләре икееллык яки картрак ботакларда барлыкка килә. 5 көнгә кадәр торалар. Марттан июньгә кадәр чәчәк аталар, көзен яңадан чәчәк атарга мөмкиннәр. Кечкенә чүлмәкләр чәчәк атуны тизләтә. ТРда кайбер гибрид (кушылгак) формаларын — Акерман Э.ын (E. ackermanii), Купер Э.ын (E. cooperi), Сабра Э.ын (E. sabra) — бүлмә гөле буларак үстерәләр. Э. ботак очларыннан һәм сабактан (8–10 *см*) үрчетелә. Гадәттә, тирән булмаган күзәнәкле киң чүлмәккә утырту уңай нәтиҗә бирә. Известьле туфрак ярамый. Яктылык яратучан, әмма туры кояш нурлары тискәре йогынты ясый. Күләгәне яхшы кичерә. Чәчәк бөреләре барлыкка килгәч, гөлне селкетергә, салкынча һәм коры бүлмәдән югары темп-ралы һәм дымлы бүлмәгә дә күчерергә киңәш ителми: бөреләре коелачак яки черияЧәк. Суны кышын уртача, язын һәм җәен мул итеп сибәргә кирәк.

**«ЭПЛА́ЙД МЕГНЕ́ТИК РЕ́ЗНЕНС»** («Applid Magnetic Resonance» — «Магнит резонансын куллану»), халыкара фәнни журнал. 1990 елдан Казанда инглиз телендә нәшер ителә. Оештыручысы һәм мөхәррире — К.М.*Салихов*. Springer Wien New York нәшрияты (Вена, Австрия) чыгара. Редакция РФА КГУ нең Казан физика-техника ин-тында урнаша. 1990 елда 1 нче томы чыга (3 чыг.), 1991 дә — 1 том (4 чыг.), 1992 дә — 1 том (6 чыг.), 1993 тән ел саен 2 шәр томда (һәрберсе 4 әр чыг.) басыла. Журнал физика, химия, биол., мед., геохимия, экология һ.б. өлкәләрдә магнит резонансы кушымталарына багышлана. Анда оригиналь мәкаләләр басыла, нигездә, магнит резонансы техникасын куллануның яңа өлкәләре һәм эксперимент алымнар буенча ЯМР, ЭПР, төш квадруполь резонанс, мессбауэр спектроскопия кушымталары һәм алымнарына багышланган язмалар, магнит резонансының актуаль мәсьәләләре буенча махсус чыгышлар дөнья күрә. Редакция 27–28 Ампер конгрессларь, Ампер коллоквиумнары һәм халыкара конференцияләр кысаларында әзерләнгән язмалар тупланмаларын бастыра. Мәгълүмат бүлегендә магнитлы резонанс һәм яңа җиһазларга багышланган конференцияләр турында хәбәрләр, ш.у. яңа китапларга рецензияләр урнаштырыла.

**ЭПОЛЕТСЫМА́Н КАПТЫРМАЛА́Р** (археол.), Пьянобор, Азелино һ.б. археол. культуралар халыклары арасында таралыш алган хатын-кыз бил каешының бронза детале.



Эполетсыман бронза билбау каптырмалары.

Формалары буенча эполетларны хәтерләтәләр. Э.к.га хас үзенчәлек — арткы ягында ыргаклы чөе булган түгәрәк аеллар һәм шул чөй жгут б-н тоташкан, арткы ягында ыргаклы пластина. Иң борынгы бил каешлары, зур булмыйча, 3–4 жгуттан торган, соңгырак дәвер эшләнмәләре 7–12 жгутлы, 30 *см* га кадәр озынлыкта булганнар, аларның авырлыгы 1 *кг* нан арткан.

*Әд.:* Х у д я к о в М.Г. Эполетообразные застежки Прикамья // Сб. ГАИМК: Бюро по делам аспирантов. Л., 1929. Т. 1; Г е н и н г В.Ф. История населения удмуртского Прикамья в пьяноборскую эпоху. Ч. 1. Чегандинская культура (III в. до н. э. — II в.н.э.) // Вопр. археологии Урала. Свердовск, 1970. Вып. 10. *Е.П.Казаков.*

**Э́ПОС** (грек. épos — сүз, хикәя), 1) әдәбият төре (лирика һәм драма б-н беррәттән), узгандагы дип фаразланган (хикәяләүче булган дип исәпләгән һәм искә төшергән) вакыйгалар турында тасвирлана; 2) жанр, халык тормышының тулы картинасын гәүдәләндергән, эпик дөньяны һәм герой-батырларны күрсәтеп биргән, үткәннәр турында героик хикәяләү (к. *Фольклор*). Халыкның тарихи хәтерен чагылдыра. Архаик-мифологик, тарихи-героик, мәхәббәт-романтик вакыйгалар турында хикәяли. Тулысынча шигъри, чәчмә һәм катнаш (шигъри һәм проза текстлар чиратлашуы) формада булырга мөмкин. Киң мәгънәдә татар Э.ы кайбер фольклор жанрларын да үз эченә ала. Эпик әсәрләр дастаннар Э.ы дип билгеләнәләр. Гадәттә Э. төркемнәргә бүленә. Беренче төркемгә батырлар турындагы элгәреге, экияти-мифологик хикәятләр («*Йиртөшлек*», «*Түләк*», «Түләк һәм Сусылу» һ.б.), икенчесенә героик дастаннар («*Ак кубек*», «*Алтаин Саин Сүмә*», «*Жик Мәргән*», «*Идегәй*», «*Чура батыр*» һ.б.), өченчесенә лиро-эпик дастаннар («*Кузы Күрпәч белән Баянсылу*» һ.б.), дүртенчесенә китаплар нигезендә иҗат ителгән күпсанлы дастаннар («*Буз егет*», «*Кыйссаи Йосыф*», «*Таһир белән Зөһрә*», «*Ләйлә белән Мәҗнүн*», «*Сәйфелмөлек*» һ.б.) керә. Татар Э.ы әсәрләре өчен сәнгать алымнарының байлыгы һәм төрлелеге хас: тәфсилле (мәс., батырның үзен, батыр атын, ат дирбиясен, гаскәри киемнәрне, коралларны һ.б.) тасвирлаулар, монологлар, диалоглар, эпитетлар, метафоралар һ.б. троплар куллану. Татар Э.ы — милли фольклорның иң аз өйрәнелгән өлеше. Бу ВКП(б) ҮКның 1944 елның 9 августындагы «*Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында*» карары нигезендә Алтын Урда тарихын, «Идегәй» дастанын, героик-батырлар турында Э.ның башка әсәрләрен өйрәнүне фактик тою б-н бәйле. 1980 елларда гына татар Э.ын фәнни өйрәнү яңадан башлана. 1984 тә «*Татар халык иҗаты*» күптомлы басмасы кысаларында беренче зур «Дастаннар» җыентыгы (төзүчесе Ф.В.Әхмәтова) нәшер ителә. Хәзерге вакытта татар Э.ын өйрәнү б-н ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының халык иҗаты бүлеге, Казан ун-ты хезмәткәрләре шөгыльләнә.

*Әд.:* У р м а н ч е е в Ф. Алтын Урда чоры татар фольклоры // Татар халык иҗаты. К., 2005; ш у л у к. Героический эпос татарского народа. К., 1984. *Ф.И.Урманчеев.*

**ЭПР**, к. *Электрон парамагнетик резонанс.*

**ЭПР СПЕ́КТРЛАРЫНЫҢ ҮТӘ́ НЕЧКӘ́ ТӨЗЕЛЕШЕ́**, төшнең магнит моменты электроннарның магнит кыры б-н үзара тәсирләшүе нәтиҗәсендә килеп чыккан парамагнит кисәкчәләр спектрларының үзара якын урнашкан сызыкларга таркалуы күренеше. Магнит кушылган парамагнит кушылмаларның сыек эремәләрендә электрон магнит моментлары арасындагы диполь-диполь тәэсир итешү нольгә кадәр уртачалана һәм ЭПР спектрларының үтә нечкә изотроп структурасы (ҮНИС) барлыкка килә. Металл комплексларында, ирекле радикалларда, ион-радикалларда парлашмаган электрон күп кенә магнетик төшләр б-н тәэсирләшә һәм ҮНИС күренеше катлаулы була; бу хәлдә ҮНИС сызыклары (ҮНИС константасы) арасындагы ара һәм сызыкларның активлыгы системадагы молекула эче үзара тәэсир итешүнең характерын чагылдыра. ҮНИСны мондый кушылмаларның ЭПР спектрларында күзәтү анализы электрон б-н магнит төшләре арасындагы тәэсир итешү рәвешен, аның молекуляр системаларда делокализациясен һәм барлыкка килгән химик бәйләнешләрнең табигатен билгеләү, ш.у. күп кенә төш спиннарының зурлыгын ачыклау мөмкинлеге бирә.

Каты парамагнит системаларда һәм монокристалларда парлашмаган электронның магнит моментлары б-н төшләр арасындагы диполь-диполь тәэсир итешү нәтиҗәсендә барлыкка килгән анизотроп ҮНС күзәтелә. Бу тәэсир сәбәпле килеп чыккан таркалу парлашмаган электронны төш б-н баглаган вектор һәм тышкы магнетик кыр юнәлеше арасындагы почмакка бәйле. Шуның өчен парамагнит монокристаллардагы ЭПР спектрларының ориентация буенча бәйле булуы күзәтелә. Каты һәм үзле мохитләрдә парамагнит молекуланың тышкы магнит кыры юнәлешенә карата хаотик урнашуы сәбәпле, йоту спектры монокристалларының ҮНИС суперпозициясе буларак уртага чыга, бу исә әлеге матдәләрдә ЭПР с.ү.н.т. сызыгы киңәюенә китерә.

ЭПР с.ү.н.т. Т.н беренче буларак инглиз физигы Р.П.Пенроз 1949 да һәм аннан бәйсез рәвештә 1950 дә Казан галимнәре С.А.Альтшулер, Б.М.Козырев һәм С.Г.Салихов ачалар.

*Әд.:* А л ь т ш у л е р С.А., К о з ы р е в Б.М., С а л и х о в С.Г. Влияние ядерного спина на резонансное парамагнитное поглощение в растворах соединений марганца и меди // Докл. АН СССР. 1950. Т. 71. *Ә.В.Ильясов.*

**ЭПШТЕ́ЙН** Товий Давидович (2.12.1895, Латвия — 25.10.1969, Казан), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1935), проф. (1935), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1945). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1921), Сембер шәһәр хастаханәсе табибе булып эшли. 1922 елдан Вотяк автономияле өлкәсенең (хәзер Удмурт Респ-касы) өлкә сәламәтлек саклау бүлеге мөдире урынбасары, мөдире. 1923 тән Казанда: 1939 га кадәр ГИДУВның социаль гигиена кафедрасында, 1930 дан каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1935–38 дә, ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссарының дәвалау эшләре буенча урынбасары. 1939–42 дә Сталинград мед. ин-тының сәламәтлек саклауны оештыру кафедрасында, бер үк вакытта институт директоры урынбасары вазифаларын башкаручы. 1942–66 да Казан мед. ин-тында (1949–54 тә — мед. тарихы, 1954 тән социаль гигиена кафедраларында, 1966 дан фәнни консультант); бер үк вакытта, 1942–46 да, ТАССР сәламәтлек саклау министры урынбасары, баш дәүләт сан. инспекторы. Хезмәтләре Татарстанда сәламәтлек саклауны оештыру һәм демографик процессларга, Казан мед. фәнни мәктәбе тарихын өйрәнүгә карый. 1957–64 тә ТАССР сан. табибләре һәм гигиена белгечләре җәмгыяте һәм ТАССР мед. тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Из истории одного советского ВУЗа. К., 1935 (автордаш); О судебных делах врачей // Казан. мед. журн. 1928. № 2.

*Әд.:* Профессор Товий Давидович Эпштейн // Казан. мед. журн. 1970. № 1.

**ЭРБЕ́Т ПА́РКЫ**, Казанның Идел буе р-нында (18 нче шәһәр хастаханәсе терр-ясендә). ТРның табигать истәлеге (1994). Мәйданы 1 *га*. Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларның исемен мәңгеләштерү максаты б-н 1988 елда, агроном-бакчачы, а.х. фән. канд. Г.Ш.Камалетдинов башлангычында булдырыла. Башта 500 Себер әрбете (гади



Эрбет паркы.

нарат тамырларына ялганган), соңрак Маньчжур чикләвеге, Амур бәрхете, чәнечкеле чыршы, көнбатыш туясы (савыры) һ.б. утыртыла. Хәзер эрбет агачлары җимеш бирү яшендә. Объект агачлы һәм куакчыл үсемлекләр интродукциясе мисалы буларак фәнни әһәмияткә ия.

**ЭРБЕ́Т ЯРМИНКӘСЕ́**, 17 йөздә — 20 йөз башында Россиядәге иң зур ярминкәләрнең берсе. Эрбет шәһәрендә (хәзер Свердловск өлкәсе) уздырыла. 17 йөзнең 2 нче чирегендә барлыкка килә. 17–18 йөзләрдә гыйнварда, 19 йөздә — 20 йөз башында февральдән алып мартка кадәр үткәрелә. Руслар һәм татарлардан тыш, Кытай, Урта Азия сәүдәгәрләре дә катнаша. Җәнлек тиреләре, тукымалар, күн эшләнмәләр, чәй, бал, балавыз, колмак, ш.у. металл эшләнмәләр, галантерия әйберләре, азрак күләмдә — бакалея һәм азык-төлек товарлары сатыла. Россия империясендә товар алмашу буенча Түбән Новгород ярминкәсеннән кала икенче: 1880 еллар-

да ярминкәнең товар әйләнеше 68 млн. сум тәшкил итә. Транссебер тимер юлыннан читтәрәк булуы сәбәпле, акрынлап әһәмиятен югалта.

*Әд.:* Хитров А. К истории г. Ирбита и Ирбитской ярмарки. Ирбит, 1872; Александров В.А. Начало Ирбитской ярмарки // История СССР. 1974. № 6.

**ЭРБЕТЧЕ́**, эрбет чыпчыгы (Nucifraga caryocatactes), карга кошлар семьялыгыннан. Европа, Азия, Төньяк Америкада яшиләр. Гәүдәсенең озынлыгы 30–40 *см*, авырлыгы 130–200 *г*. Каурый капламы куе һәм йомшак. Зур ак чуарлы куе көрән төстә. Башының өсте, канатлары һәм койрыгы кара, койрык очында киң ак буй бар. Башы зур һәм яссы. Томшыгы нәзек, озын. Борын тишекләре нечкә чәчсыман каурыйлар б-н капланган. Ылыслы урманнарда яши. ТРда еш кына Кама алдында (оялау ареалының көньяк чиге), гадәттә, августтан кар төшкәнчегә кадәр очрый. Оясын куе урманнарның яшерен почмакларында кора. Ылыслы агачларның орлыклары, бөҗәкләр, тычкансыман кимерүчеләр, моллюсклар б-н туклана. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



**Э́РДМАН** Фёдор (Иоганн-Фридрих) Христофорович (1778, Виттенберг ш. — 16.1.1846, Висбаден ш.), терапевт, мед. һәм хирургия д-ры (1802), табигыять тарихы профессоры (1804), патология һәм терапия ординар профессоры (1807). Виттенберг ун-тын тәмамлый. 1800 елдан Виттенберг ун-тында эшли. 1810–17 дә Казан ун-тының патология һәм терапия каф. мөдире. 1818 дән Германиядә. Хезмәтләре физикага, Сергиевск минераль чыганагы (Самара өлкәсе) суының үзлекләрен өйрәнүгә карый. Э. Казан ун-ты каршындагы терапия клиникасына нигез сала (1816). 1820 дә Россиядә беренче буларак стетоскоп куллана. Казан медикларыннан беренче булып Россия Фәннәр академиясенә сайлана. Казан ун-ты табиблек фәннәре бүлегенең беренче деканы.

Хезм.: Извлечения из описания Сергиевских минеральных вод, составленного профессором Эрдманом для С.-Петербургской медицинской академии // Казан. известия. 1811. № 19 — 20; Серный источник близ г.Тетюши // Казан. известия. 1812. № 18 (автордаш); Beitrage zur Ktnntniss der Innern von Russland: V. 1 — 3. Riga-Derpt-Lps., 1822 — 26.

*Әд.:* Русский биографический словарь. СПб., 1912.Т.24; Немецкие учёные-профессора Казанского университета. К., 2004.

**Э́РДМАН** Фёдор Иванович (Friedrich Franz Ludwig Erdmann) (15.3.1793, Людвигслюст ш., Мекленбург-Шверин герцоглыгы — 26.2. 1862, Казан), шәркыятьче галим, философия д-ры. Росток һәм Гёттинген ун-тларын тәмамлаганнан соң, Росток ун-тында эшли. 1818 елдан Казан ун-тында: шәрекъ телләре ординар профессоры, 1825 тән *Шәрекъ бүлегендә* гарәп һәм фарсы телләре каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1824 тән, нумизматика кабинеты һәм сирәк табылдыклар кабинеты мөдире; 1822–32 дә, 1835–36 да тел-әдәбият бүлеге, 1841–45 тә филос. ф-ты деканы; 1822 дән Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе укытучысы, 1828–45 тә шәрекъ язмалары цензоры. 1832–35 тә пед. ин-ты студентлары инспекторы һәм директоры. 1850 дән Новгород губернасы уч-щеләре директоры. 1825 тә Казан, Оренбург һәм Вятка губерналарының борынгы ядкәрләрен тикшерү максатында Оренбург шәһәрендә һәм Кама буенда фәнни экспедициядә була. 1820 елларда Университет советы алдына күп тапкырлар татар теле грамматикасын һәм сүзлеген әзерләү зарурлыгы турындагы мәсьәләне куя, 1829 да «Татар теленең тулы сүзлеген төзү программасы»н («Программа для составления полного татарского словаря») тәкъдим итә. Хезмәтләре мөселман халыклары тарихы, этнографиясе, нумизматикасы, әдәбияты, телләренә карый. Париж Азия җәмгыяте, Лондон Азия җәмгыяте, Копенгаген төньяк борынгы ядкәрләр җәмгыяте, Мәскәү тарих һәм Россия борынгы ядкәрләр җәмгыяте әгъзасы. Шәрекъне өйрәнүгә караган китаплар, кульязмалар һәм акчалар буенча күренекле коллекционер. 1875 тә Император гавами китапханәсе (хәзер — Россия милли китапханәсе) аның коллекциясеннән гарәп, фарсы һәм төрки телләрдәге 39 кульязманы сатып ала. 1984 тән Э. китапханәсендәге китапларның бер өлеше Бөтенроссия чит ил әдәбияты китапханәсенең сирәк китаплар бүлегендә саклана.



Ф.И. Эрдман.

*Әд.:* Отчёт Императорской публичной библиотеки за 1875 г. СПб., 1876. С.28–45; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Валеев Р.М. Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX в. – 20 гг. XX в.). К., 1998; Зайцев И. О книжном собрании Ф.Эрдмана, находящемся в отделе редких книг Всероссийской государственной библиотеки иностранной литературы // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2003. № 1/2.

*Р.М.Вәлиев.*

**ЭРЕ́ АК ТОКЫМЛЫ́ ДУҢГЫ́З**, күп төрле продукция бирә торган йорт хайваны.19 йөздә Англиядә җирле соң өлгерүче дуңгызларны тиз өлгерүче Кытай һәм күп үрчемле Неаполь, Португалия токымнары б-н катлаулы кушу юлы нәтиҗәсендә китереп чыгарыла. Россиягә берничә тапкыр кертелә. Дәвамлы нәсел үрчетү эшчәнлеге нәтиҗәсендә илнең ике төп төргә (ит һәм күбесенчә ит-май) караган яңа үз токымы булдырыла. Терлекләр төрле климат шартларына яраклашкан, тиз өлгерүчән, гәүдә төзелешләре камил, нык. Ата дуңгызларның авырлыгы 320–350 *кг* га, ана дуңгызларныкы — 220–250 *кг* га, интенсив тукландыру шартларында 6 айлык яшь дуңгызларның авырлыгы 100 *кг* га житә. 1 *кг* артым алу өчен 3,9–4 азык берәмлеге тотыла. Ана дуңгызлар бер балалаганда 10–12 бала китерә. Э.а.т.д. ларны башка токымнар б-н сәнәгый кушып, күп кенә яңа токымнар китереп чыгарыла. БДБ илләрендә һәм РФдә төп планлы токым исәпләнә, Европаның барлык диярлек илләрендә, АКШ, Канада, Кытай, Корея, Япония, Яңа Зеландиядә үрчетелә. ТРда токымлы дуңгызларның 98% ын тәшкил итә, 25 нәсел үрчетү хуҗалыгында, ш.и. Кукмара р-нының «Урал», Әгерҗе р-нының «Чишмә», Чүпрәле р-нының «Чынлы», Мөслим р-нының «Уңыш», Теләче р-нының В.И.Ленин исем., Тукай р-нының «Сосновоборский», Балтач р-нының Тимирязев исем. һ.б. хуҗалыкларында үрчетелә. 2017 ел башына 76600 баш дуңгызга бонитировка ясала.



Эре ак токымлы дуңгыз.

*Әд.:* Ладан П.Е., Мысик А.Т. Породы свиней. М., 1981; Генетические ресурсы сельскохозяйственных животных в России и сопредельных странах. СПб., 1994.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**ЭРЕ́ ПАНЕЛЬЛЕ́ ЙОРТЛА́Р ТӨЗЕЛЕШЕ́**, торак йортлар төзүнең индустриаль алымы. Йортлар төзү з-длары һәм комб-тлары тарафыннан климат һәм технол. шартларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла. Эре панельләр куллану йортларны төзү вакытын 1,5–2 тапкыр кыскартырга һәм төзелеш мәйданчыгында хезмәт чыгымнарын киметергә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта, кирпеч йортлар б-н чагыштырганда, 1 $м^2$ торак мәйданның смета бәясе 12–15% ка арзанрак. 1950 еллар ахырыннан ТР терр-ясендә Э.п.й.т. бөтенсоюз 1.605, 464 серияләре җирлегендә эшләнгән типлы проектлар буенча алып барыла. Торак йортлар макс. 3,2×5,76 *м* зурлыктагы «бүлмәлек» панельләре булган күтәрүче аркылы эчке һәм тышкы диварлардан тора. Э.п.й.т. даими рәвештә камилләштерелә: чама б-н һәр 5 ел саен проектлау нормаларына һәм типлы проектларга төзәтүләр кертелә, эшләнмәләрнең икътисади һәм җылылык-техник сыйфатламалары, конструкция чишелешләре һәм фасадларның бизәлеше яңартыла. Минимальләштерелгән кухнялы, катнаш сан.узеллы, үтәли йөрелмәле бүлмәләре булган беренче типлы иркенрәк бүлмәле, сан. узеллары аерым, лоджияле серияләр (125, 90, 121) б-н алышына. Катлар саны 9–10 га кадәр арта. Почмактагы, борылыштагы һәм иң ягындагы секцияләр төзелешне төрләндерәләр. 1980 елларда ТР шәһәрләрендәге (Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Лениногорск һ.б.) торак йортлар тулаем диярлек эре панельле булалар. Бу вакытка Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Лениногорск шәһәр-

ләрендә һ.б. да Э.п.й.т. з-длары төзелә. 1990–98 дә тораклар төзүнең гомуми күләмендә Э.п.й.т. өлеше 2 тапкыр кими. Ул башлыча тузган торак фондын бетерү программасы кысаларында гамәлгә ашырыла. ТР Э.п.й.т. з-дларының серияле эшләнмәләре җирлегендә төзелешкә яңа — ригельсез-каркаслы, каркаслы-панельле күтәрүче-терәк системалары кертелә, тышкы диварлар өчен җылылык каршылыгына сәләтле өч катламлы эффектив панельләр һәм данәле җылыткыч материаллар кулланыла. Андый күтәрүче-терәк системалары бинаның архитектур күренешен, фатирларның күләм-планировка чишелешен, аларның уңайлыкларын күпкә яхшырту, заказчының теләкләрен исәпкә алу мөмкинлеге бирә.

*Г.П.Никитин, Б.С.Соколов.*

**Э́РИХ** (Erich) Иван Иванович (1755, Германия, Эрфурт ш. — ?), тарихчы, тел галиме. Эрфурт, Йена һәм Гёттинген ун-тларын тәмамлый. Өйдә дәресләр бирә, Түбән Новгород әсасый халык уч-щесендә — немец теле, 1799–1804 елларда Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә латин теле укыта. 1805–19 да Казан ун-тында, проф. (1814). Грек-латин йола ономастикасына караган хезмәтләр авторы.

*Әд.:* Загоскин Н.П. Деятели Императорского Казанского университета. 1805 г. — 1900 г. К., 1900. *С.М.Михайлова.*

**«ЭРМИТА́Ж-КАЗА́Н»**, Казандагы күргәзмәләр үзәге, РФдә Дәүләт Эрмитажының беренче вәкиллеге, «Казан Кремле» тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгының структур бүлекчәсе. ТР МКның 2004 ел 31 март карары б-н оештырыла. 2005 нең 23 августында Казанның 1000 еллыгына ачыла. Казан Кремле терр-ясендә, элекке Юнкерлар уч-щесе (19 йөз уртасы, архит-ра истәлеге) бинасында урнашкан. Экспозиция мәйданы — 870 *м*². «Э.-К.» үзәгендә Дәүләт Эрмитажы тупланмасыннан 2005 тә — «Алтын Урда: тарих һәм мәдәният», 2006 да — «Дәүләт Эрмитажы тупланмасыннан XVI йөз — XX йөз башы Көнбатыш Европа чигүе. Интерьер һәм костюм», 2007 дә — «Ат бәрабәренә — ярты патшалык. Дөнья мәдәниятендә ат», «Эрмитажда рус сәнгате. XIX йөз – XX йөзнең беренче чиреге күренекле һәм онытылган осталары», 2008 дә — «Кытайдан алып Европага кадәр. Ислам дөньясы тарихы», 2009–10 да — «Аллалар токымы. Борынгы һәм яңа сәнгатьтә антик геройлар», 2010–11 дә — «17–18 йөзләрдә Франция сәнгате», «Зиннәтле корал», 2011–12 дә — «Испания сәнгате», 2012–13 тә — «Евразия күчмә халыклары империя юлында», «Олимпия: вакытны җиңү», 1913–14 тә «Француз импрессионистлары һәм алар дәвере», 2015–16 да «Италия образлары», 2017–18 дә «Петербург фарфоры» һ.б. әһәмиятле күргәзмәләр уздырыла. «Э.-К.»да Эрмитажның музей-белем бирү программалары буенча мәктәп балалары, яшьләр, музейга килүче аерым кешеләр б-н эшләү һәм актуаль сәнгатьне, дөнья киносы тарихын өйрәнү буенча укыту-белем бирү һәм методик үзәк оештырыла. Дәресләр махсус җиһазландырылган компьютер бүлмәләрендә алып барыла. Эрмитажның әйдәп баручы хезмәткәрләре тарафыннан дөнья сәнгате һәм мәдәнияте тарихы буенча лекцияләр циклы укыла. Җитәкчесе — О.И.Пиульская (2005 тән).

**ЭРО́ЗИЯЛӘНГӘН ҖИРЛӘРНЕ́ САКЛА́У**, туфракның өске катламын су, җил б-н һәм хуҗалык эшләре нәтиҗәсендә зарарланудан саклау буенча чаралар комплексы. Эрозия туфракның сөрелә торган катламын бетерә, булган чокырларның зураюына, яңалары барлыкка килүгә китерә, туфракның уңдырышлылыгын киметә, а.х. файдалану җирләрен игенчелек өчен яраксызга әйләндерә, су баса торган табигый терлек азыгы үсә торган җирләрне, сазлыкларны, сулыкларны һәм елгаларны ләмләндерә. Татарстанда барлык сөрүлек җирләр эрозиягә дучар ителгән, шуларның 1,5 млн. *га* — уртача һәм көчле дәрәҗәдә. Кама алды һәм Югары Идел алдында линияле-чокырлы эрозия киң таралган. Булган 20 меңнән артык чокырның зураюы сәбәпле, ел саен ТРда якынча 1 мең *га* җир а.х. әйләнешеннән чыга. ТР шартлары өчен а.х. файдалану җирләренең (сөрүлек, табигый терлек азыгы үсә торган җирләр, су баса торган болыннар һәм көтүлекләр) һәм чокырлы-сызалы җирләрнең һәр категориясе буенча зональ туфрак саклау комплекслары эшләнгән, тәкъдим ителгән һәм гамәлгә ашырыла:

1. Терр-яне контурлы-буйлы һәм контурлы-туры линияле итеп оештыру (к. *Җир төзүчелек*).

2. Агротехника, туфрак саклау чаралары системасының бүленеше:

– тигез кырларда, 1°ка кадәрге участок һәм сөзәклекләрдә гадәти агротехника кулланыла;

– 1–2°лы сөзәклекләрдә барлык операцияләр дә аркылы юнәлештә уздырыла, төп эшкәртү тирәнәйтеп, рәт аралары куышлар ясап башкарыла;

– 2–3°лы сөзәклекләрдә төп туңга эшкәртү яссы кискечләр б-н, тирән көпшәкләндергечләр һәм алдан камылны йомшартып, әйләндереп капламый торган сабан б-н уздырыла;

– 3–5°лы сөзәклекләрдә катламнарны әйләндереп капламый торган төп эшкәртү кулланыла;

– 5–7°лы сөзәклекләрдә алда әйтелгән ысулларга культураларны буй-буй итеп урнаштыру өстәлә, ягъни 80–100 *м* киңлектәге берьеллык культуралар чәчелгән буйлар 11–12 *м* киңлектәге күпьеллык үләннәр чәчелгән буйлар б-н аралаштырыла.

3. Ышыклаучы урман утыртмалары системасын булдыру (к. «Чулпан» табигый туфрак тыюлыгы терр-ясе фоторәсеме).

4. Эрозиягә каршы корылмалар — суны тоткарлаучы валлар, траншея-канаулар, читәнле буалар, буалар һ.б. төзү.

5. Сөзәк җирләрне террасалау, болынландыру, урманландыру.

6. Кайбер очракларда җирләрне консервацияләү, хуҗалыкларның специальләшүен үзгәртү; игенчелектә фәнни җир саклау нигезләрен бозган өчен җирдән файдаланучыларны административ һәм җинаять җаваплылыгына тарту, ТР Җир кодексының 115 маддәсе нигезендә җир участогына булган хокукларын мәҗбүри туктату.

ТРда Э.җ.с. буенча ел саен максатчан юнәлештә эш алып барыла. Респ-када 558 буа, сулыклар һәм башка гидротехник корылмалар бар. 2000–03 елларда 317 су тоткарлаучы вал, 135 су агызучы корылма, 6525 читәнле буалар төзелә, 4693,9 *га* чокырлы-сызалы һәм 1564 *га* кыр ышыклаучы урманнар утыртыла. 2003 тә агротехник, эрозиягә каршы чаралар уздырыла: камыл йомшарту 300 мең *га* да, җирне әйләндереп капламый торган һәм яссы кискечләр белән төп эшкәртү 432 мең *га* да, микрорельефны тигезләү 340 мең *га* да, салам кертеп әйләндереп каплатып сөрү 336 мең *га* да, күпьеллык үләннәр чәчү 47,7 мең *га* да башкарыла. ТРда үзләштерелә торган адаптив-ландшафтлы игенчелек системасында 375 мең *га* (сөрүлек мәйданының 10,7% ы) туфрак саклаучы чәчү әйләнешенә бирелә. Бу җирләрнең төп (60%тан ким булмаган) өлешен нык эрозияләнгән җирләрнең уңдырышлылыгын кабат кайтаруга яр-







«Эрмитаж-Казан» күргәзмәләр үзәге. Күргәзмә экспозицияләреннән фрагментлар:
1. «Евразия күчмә халыклары империя юлында». 2012–13; 2. «Зиннәтле кораллар». Эрмитаж тупланмасыннан. 2011; 3. «Олимпия: вакытны җиңү». 2013.

дәм итә торган күпьеллык кузаклы-кыяклы катнаш культуралар били. Күпьеллык үләннәр сыйфатында иң чыдам һәм җирнең уңдырышлылыгына таләпчән булмаган люцерна, эспарцет һәм аларның кыяклы үләннәр б-н катнашмасы кулланыла. Э.җ.с. максатында 225 мең *га* бик нык эрозияләнгән сөрүлек җирләр табигый файдалану җирләре (печәнлек һәм көтүлекләр) итеп күчерелә. Ш.у.к. *Туфрак эрозиясе*.

Чыг.: Земельный кодекс Республики Татарстан. К., 1998; Государственный доклад «О состоянии и использовании земель в Республике Татарстан в 2003 году». К., 2004.

*Әд.:* Комплекс противоэрозионной защиты земель Татарии. К., 1975; Рекомендации по обработке почвы в севооборотах колхозов и совхозов Татарской АССР. К., 1983; Пухачёв А.П. Почвам — надёжную защиту. К., 1984; Система ведения отраслей агропромышленного комплекса Республики Татарстан. К., 1992.

*А.П.Пухачёв.*

**Э́РЬЗЯ** (псевд. — мордва этник төркеменең үзатамасыннан, чын фамилиясе Нефёдов) Степан Дмитриевич (27.10. 1876, Сембер губ., Алатырь өязе Баево а. — 24.11.1959, Мәскәү; Мордва Респ-касының Саранск шәһәрендә җирләнә), Россиянең күренекле скульпторы. Алтышево авылында чиркәү каршындагы мәктәпне тәмамлый. 1893 елда Э. Казанга килә, П.А.Ковалевскийның иконалар язу остаханәсендә укый һәм эшли, аның җитәкчелегендә Арча шәһәрендәге чиркәүне бизи,



С.Д.Эрьзя. «Бию (Балерина)». 1930.
С.Д.Эрьзя исемендәге Мордва республика сынлы сәнгать музее.

Казан сынлы сәнгать уч-щесендә дәресләр ала. Мәскәүдә Строганов сәнгать-сәнәгать уч-щесендә (1901–02), Мәскәү сынлы сәнгать, скульптура һәм архит-ра уч-щесендә (1902–06) С.М.Волнухинда һәм П.П.Трубецкойда укый. 1906–14 тә Италиядә, Франциядә яши, дөньякүләм танылу ала; Венециядә, Миланда үткәрелгән халыкара күргәзмәләрдә (1909), Париждагы Көзге салонда (1912) катнаша. 1918 дән башлап Россиядә — Екатеринбург, Новороссийск, Батуми, Баку шәһәрләрендә яши. Рус скульпторлары җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1926). 1927–50 дә Аргентинада яши, 1951 дә Мәскәүгә әйләнеп кайта.

Портрет остасы, монументалист, станлы композицияләр авторы буларак, Э. дөнья сәнгате үсешендәге яңа стиль тенденцияләрен (модерн) һәм мордва халкының агачка уеп ясау традицияләренә таянып иҗат итә. Аргентинада Э. иҗатына сельва индеец кабиләләре сәнгате зур йогынты ясый. Әсәрләрен гипс, мәрмәр, бронза, тимер-бетоннан ясый. Аның агач эшләнмәләре милли үзенчәлек б-н аерылып тора (Кавказ имәне, чикләвек, Көньяк



С.Д.Эрьзя. «Испан кызы». 1942.
С.Д.Эрьзя исемендәге Мордва республика сынлы сәнгать музее.

Америка агачлары — альгарробо, квебрахо, урундай); монументаль эшләрен цементтан, гипстан башкара. Төп әсәрләре: «Эшләпәле хатын» (1906), «Сагыш» (1908), «Кул-аяклары кадакланган Христос» (1910), «Автопортрет», «Эрьзя хатын-кызы», «Монгол хатын-кызы» (барысы да — 1915), «Мордва хатын-кызы башы» (1917), «Һава» (1919), «Тоткын» (1920), «1905 елгы революция корбаннары» (1926), «Бетховен», «Леда һәм аккош» (икесе дә — 1930), «Лев Толстой», «Ялангач хатын-кыз» (икесе дә — 1930), «Моисей» (1932), «Ялкынлы» (1934), «Мордва крәстияне» (1037), «Микеланджело», «Сократ» (икесе дә — 1940), «Инк кызы», «Аргентина хатын-кызы» (икесе дә — 1941), «Мордва карты» (1944), «Хатын-кыз портреты» (1954), «Мәхәббәт» (1955) һ.б.

Әсәрләре Третьяков галереясында, Рус музеенда, Мордва Респ-сының С.Эрьзя исем. сынлы сәнгать музеендагы Эрьзя галереясында һ.б.да, күпчелеге чит илләрдә саклана. Туган авылы Баеводa Э. ның Музей-йорты ачыла.

*Әд.:* Полевой Б. С.Эрьзя (Степан Дмитриевич Нефёдов). Саранск, 1961; Сутеев Г.О. Скульптор Эрьзя: Биографические заметки и воспоминания. Саранск, 1968; Абрамов К.Г. Сын эрзянский: В 3 кн. М., 1974–77; Степан Дмитриевич Эрьзя (Нефёдов): Альбом. Саранск, 1981; Эрьзя на Родине: Альбом. Саранск, 1996; Скульптор Эрьзя: Кн.-альбом. Саранск, 2006; Розенберг Н.А. Степан Эрьзя. Аргентинский период: на пересечении культурных традиций. СПб., 2007.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЭСЕРЛА́Р**, к. *Социалист-революционерлар партиясе.*

**ЭСКӘККОЙРЫКЛА́Р** (Dermaptera), бөҗәкләр отряды. Пермь чорыннан билгеле. Гәүдәсе озынча, сыгылмалы. Алгы канатлары (канат өслекләре) — кыска, тиречел, арткылары — элпәле. Корсагының арткы очында келәшчәсыман үсентеләр — саклану һәм һөҗүм итү органнары бар (ата затларда ана затларга караганда аның төзелеше катлаулырак). Аяклары йөрүгә җайлашкан. Ана бөҗәкләр күкәйләрен җирдә махсус казылган чокырчыкларга яисә өннәргә сала һәм аларны личинкалары чыкканчыга кадәр саклый. 1000 гә кадәр төре билгеле. Татарстан терр-ясендә аеруча гади эскәккойрык (Forticula auricularia) һәм бакча эскәккойрыгы (F. Tomus) таралганнар. Э. — дымлылык һәм җылылык яратучылар. Төнлә активлар, көндез ташлар, коелган яфраклар астына, ярыкларга һ.б.га качалар. Кайвакыт йортларга һәм умарта ояларына керәләр. Вак умырткасызлар һәм үсемлек азык б-н туеналар. Күпләп үрчегән очракта культуралы үсемлекләргә зарар китерергә мөмкиннәр.

*С.М.Шәфигуллина.*

**ЭСПАРЦЕ́Т** (Onobrychis), кузаклылар семьялыгыннан күпьеллык, сирәгрәк берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы, терлек азыгы үсемлеге. 130 дан артык төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Африкада таралган. ТРда бер төре — комлы Э. (O.arenaria), болынлы һәм ташлы далаларда, күбрәк респ-каның көньяк р-ннарында үсә. Үзәк тамырлы. Сабаклары тармакланган, туры. Яфраклары катлаулы, парсыз каурыйсыман. Чәчәкләре себеркәчле, ачык-алсу, куе башаксыман чукларга җыелган. Май–июльдә чәчәк ата. Җимеше — кузак, түгәрәк, чикләвексыман, бер орлыклы, тешле-чәнечкеле, җепселле челтәр б-н. Бөҗәкләр, нигездә умарта кортлары ярдәмендә серкәләнә, баллы. Корылыкка чыдам үсемлек, ачы һәм сазлыклы туфраклардан тыш, барлык туфракларда диярлек яхшы үсә. Яшел масса, печән өчен үстерелә. Барлык а.х. терлекләре яратып ашый. Составында углеводлар (9,6%), аксым (4,4%), майлар (1,6%) бар. 100 *кг* яшел массасында 22 азык берәмлеге һәм 3,1 *кг* үзләштерелә торган протеин, печәнендә 54 азык берәмлеге һәм 10,1 *кг* үзләштерелә торган протеин бар. Корткычлар: орлыкашарлар, эспарцет бөртекчәсе, эспарцет эвритомасы, эспарцет чәчәге черкие, эспарцет чәчәкашары, эспарцет трипсы. Авырулары: ончыл чык, тутык, фузариоз. ТРда чәчәргә рөхсәт ителгән сортлары: «Песчаный 1251», «Песчаный 22». 2009 да 18,2 мең *га* мәйданда үстерелә, яшел массасының уңышы — 1 *га* дан 250–270 *ц*, печән уңышы — 1 *га* дан 35–38 *ц*.



Гади эспарцет.

*Әд.:* Гладкий М.Ф., Корнилов А.А., Яценко Я.Л. Эспарцет. М., 1971.

**ЭССЕ́** (фр. essai — тәҗрибә, каралама), предметның эчтәлеген тулысынча ачып бирүне дәгъваламаган, конкрет сәбәп яки мәсьәлә буенча шәхси кичерешләрне һәм фикерләрне чагылдырган кече күләмле һәм ирекле композицияле проза әсәре. Фәлсәфи, тарихи-биографик, публицистик, әдәби-тәнкый-

ди, фәнни-популяр характерда була. Татар әдәбиятында Р.Фәйзуллин («Тукай, Бабич эзеннән», «Нечкә күңелле, батыр йөрәкле»), Р.Гатауллин («Пушкин бар!», «Горурлык хисе», «Моң шагыйре») һ.б. иҗатларында очрый.

*Әд.:* Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007.

*А.А.Шәмсутова.*

**ЭСТАЧИ́** (Остачы) авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 9 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Киндерле елгасы буенда. 2010 елда 83 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 52%, татарлар — 46%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1565 — 67 дән рус чыганакларында Новые Меньшие Естачи исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Естачи буларак та мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, токарьлык эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Э.да тимерче алачыгы, җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 190,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощаково волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 53, 1782 дә — 32 ир-ат; 1859 да — 83, 1897 дә — 158, 1908 дә — 159, 1920 дә — 186, 1926 да — 216, 1938 дә — 296, 1949 да — 250, 1958 дә — 167, 1970 тә — 129, 1989 да — 516, 2002 дә — 315 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ЭСТАЧИ́ (ОСТАЧЫ́) СӨЗӘКЛЕГЕ́**, табигать истәлеге. Биектау р-ны терр-ясендә, Эстачи авылы янында урнашкан. Киндерле елгасы үзәненең сулъяк ярындагы көньяк сөзәклек. Урман зонасындагы party далаланган болын участогы. 1986 елда билгеләнә. Мәйданы 6,85 *га*. Флорасы корылыклы болын төрләрен (нәзек кырчыл, гади күрән, болын сүсәне, кырмыска борчагы, тычкан борчагы, болын кырлы борчагы, болын тукранбашы һ.б.) һәм дала флорасы элементларын (бүлбеле кияү камчысы, дала шалфее, тау тукранбашы, Дания мәче борчагы, Венгр мәче борчагы, дала сүсәне һ.б.) үз эченә ала. Язгы утчәчәк (ТР флорасының сирәк төре) киң таралган.



Эстачи сөзәклеге.

**ЭСТӘРЛЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама арьягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 53,3 *км*, бассейнының мәйданы 645 $км^2$. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Азнакай р-нында ага. Елга башы урман массивында, Балтач авылыннан 7 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Түбән Эстәрле авылыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 295 *м*, тамагыныкы — 86 *м*.

Су җыелу мәйданы елга кушылдыкларының үзәннәре б-н нык кына ергаланган калкулыклы тигезлектән тора. Субүләрнең өстенлекле биеклекләре 200–220 *м*. Рельефы яруслы (баскычсыман бусагалы): югары баскыч Чатыр тауның калдык сыртларына туры килә (биеклеге 321 *м* га кадәр), түбән агымында елга үзәненең ике ягы буенча түбәнге ярус урын алган. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. Э. үзәне асимметрияле. Сөзәклегенең ике ягында да аллювиаль террасалар урнашкан. Күп кенә урыннарда елга үзәне



Эстәрле елгасы.

сөзәклекләре 4–5 *м* тирәнлектәге озынча тар уйсулыклардан торучы ерым һәм сызалар б-н кискәләнгән. Кайбер ерымнар ярыксыман формада, уемнарның тирәнлеге 100 *м* га, озынлыгы 5 *км* га кадәр. Э. үзәнендә карст бүрәнкәләре бар. Э., аның кушылдыклары үзәннәре сөзәклекләрендә һәм субүләрлрдә имән, юкә, усак агачларыннан торучы яфраклы урманнар очрый; көньяк һәм көньяк-көнбатыш сөзәклекләре, нигездә, ассоциацияләрдән (солычалы кылган, солычалы-йончалы төрле үләнле болыннар) торучы дала үсемлекләре б-н капланган. Тугае ике яклы, югары агымында киңлеге 50–100 *м*, түбән агымында — 1,5 *км* га кадәр, ком-чуерташтан тора. Төбе балчыклы,кайбер урыннарында ташлы.

Э.нең 16 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Мәнәвез (13,6 *км*), Мәнәвез (13,8 *км*), Вәрҗәде (12,8 *км*) — сул, Чалпаймас (9,6 *км*), Сарсаз (13,6 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле бассейнының югары агымында 0,3 $л/с{\cdot}км^2$ дан түбән агымында 0,1 $л/с{\cdot}км^2$ га кадәр.

Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90–110 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 66 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана һәм якынча 30 көн дәвам итә. Җәен, суы иң аз вакытта, су биеклеге тотрыклы, яңгыр ташкыннары сизелерлек үзгәреш бирми. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,56 $м^3/с$. Елга ноябрь уртасында туңа. Боз кату уртача 160 көн дәвам итә. Бассейнда кар капламының уртача биеклеге 40–42 *см*, кыш дәвамында кар уртача 115 *мм* калынлыгында ява. Суы хлорид-гидрокарбонат-натрийлы, югары агымында гидрокарбонат-сульфат-магнийлы типта, язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*, Әсәй авылы янында — 3500 *мг/л* га кадәр.

Бассейнда суының гомуми күләме 7 млн. $м^3$ булган 13 буа бар. Су ресурслары сәнәгать һәм а.х. пр-тиеләрен су б-н тәэмин итү өчен файдаланыла. ТРның табигать истәлеге. Э. бассейнында *Чатыр тау* комплекслы табигать саклаулыгы урнашкан.

*О.Н.Урбанова.*

**ЭСТӘРЛЕБА́Ш МӘДРӘСӘСЕ́**, Уфа губернасы Эстәрлетамак өязе Эстәрлебаш авылындагы уку йорты (хәзер Башкортстан Респ-касының Эстәрлебаш р-ны). 1720 елларда нигез салына. 19 йөздә *Нигъмәтулла әл-Эстәрлебаши* (Тукаев) һәм аның уллары Мөхәммәдхарис һәм Мөхәммәдхаррас җитәкчелегендә зур уку йортына әверелә, анда 500 гә кадәр шәкерт санала. Мәдрәсә 25 бинада урнаша. Укыту гадәти Бохара системасында алып барыла, тел фәннәре, ислам дине кагыйдәләре, мантыйк югары дәрәҗәдә укытыла. Укытучылары арасында Ш.*Зәки*, Г.*Чокрый* була. 19 йөз ахыры – 20 йөз башында М.М.*Тукаев* җитәкчелегендә Э.м. сыйныф-дәрес системасы буенча яңа ысуллы мәдрәсәгә әверелә, анда рус теле, тарих, география, табигать белеме укытыла. Шәкертләре арасында — М.*Акмулла*, М.*Солтангалиев*, башкорт язучылары Г.Рәфикый, Т.Янәби. 1921 дә ябыла, аның җирлегендә пед. уч-ще оештырыла.

*Әд.:* Т у к а е в М. Тарих Стәрлебаши. К., 1899; Ф а р х ш т а т о в М.Н. Народное образование в Башкирии в пореформенный период. 80–90-е годы XIX в. М., 1994;

**ЭСТӘРЛЕБА́Ш (СТӘРЛЕБАШ) РАЙОНЫ́**, БРның көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында Карагыш р-ны буларак оештырыла, 1931 нең 6 мартында Э.р.дип үзгәртелә. Мәйданы — 1609 $км^2$. Үзәге — Эстәрлебаш авылы (Уфадан 182 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 18207 кеше (2017). 2002 дә — 12,5 мең, 2010 да 10,9 татар яши. Районда 69 торак пункт исәпләнә, шуларның 21е — татар, 5 се — башкорт-татар, 1 се — татар-чуаш, 1 се — рус-башкорт-татар авылы. Иң зур татар авыллары: Эстәрлебаш (2010 да — 5930 кеше), Тәтер-Арыслан (2016 да — 916 кеше). Татарларның күпчелеге (50% тан артыгы) район үзәгендә яшиләр. Иң борынгы авыллар: 18 йөз уртасында *Каргалы бистәсеннән* күчеп килүчеләр нигезләгән Айдарәле, Яшергән, Түбән Ибрай. Рев-циягә кадәр төбәк татарлары һ.б. мөселман халыкларның зур дини үзәге булып *Стәрлебаш мәдрәсәсе* тора; шагыйрьләр М.*Акмулла*, Ш.*Зәки*, Г.*Чокрыйның* хезмәт эшчәнлеге шушы мәдрәсә б-н бәйле,

1913 тә монда акад. В.В.*Бартольд* була. 1906 да Эстәрлебашта рус-татар, 1909 да — татар мәктәбе, 1912 дә «Шәрекъ» китапханәсе ачыла. 1934 тә Э.р.нда колхоз-совхоз театры оештырыла, муз. бизәүче булып Р.Ә.*Мортазин* эшли. Хәзерге вакытта районда татар, башкорт һәм рус телләрендә «Стәрлебаш чишмәләре» – «Стәрлебаш шишмәләре» – «Стерлибашевские родники» г-талары нәшер ителә. 2008/09 уку елында Э.р.ның 11 мәктәбендә 1 — 4 сыйныфларда укыту татар телендә бара, 5 — 11 сыйныфларда татар теле фән буларак өйрәнелә. Район мәдәният йорты каршында «Ядкәр»фольклор коллективы, татар халык театры эшли. Э.р.язучыларының «Илһам чишмәләре» әдәби берләшмәсе эшли. Районда сәясәт эшлеклесе М.Х.*Солтангалиев*, шагыйрь Ә.М.*Синугыл*, техник фән. д-ры, язучы З.Л.*Зәйнуллин* туган.

*Әд.:* Тукаев М.Тарих Стәрлибашы. К., 1899; Я р м ө х ә м м ә т о в Н.А. Мәгърифәт һәм илһам чишмәсе. Стәрлетамак, 2004; С а л и х о в Х.К. Хәлекәйнең чал тарихы. Стәрлетамак, 2004; Ш ә я х м ә т о в Ш., К у л у е в А. Тормыш сынауларын җиңеп. Стәрлетамак, 2005; М а х м у д о в М.Г. Стерлибаш, горжусь твоей судьбою. Уфа, 2000; Я р м у х а м е т о в Н.А. Жизнь течёт (История Тятер-Арсланово). Уфа, 2000; ш у л у к. Шежере жителей с. Тятер-Арсланово Стерлибашевского района Башкортостана. Уфа, 2006.

**ЭСТӘРЛЕТАМА́К** шәһәре, БР ның көньягында, Уфа шәһәреннән 130 *км* көньяктарак урнашкан. 1766 елда нигез салына. Халкы — 280233 кеше (2017). Татарлар саны: 1970 тә — 40284, 1979 да — 52075, 1989 да — 60947, 2002 дә — 60779, 2010 да — 64310 кеше. 1906 да татар китаплары нәшер итү һәм сату б-н шөгыльләнүче «*Каләм*» нәшрияты, 1910 да «*Нур*» басмаханәсе ачыла; 1912 — 1918 дә «*Иршад*» нәшрияты эшли, ул татар китаплары һәм вакытлы матбугат нәшер итү һәм сату б-н шөгыльләнә. Татар телендә «*Мәгариф эшләре*» (1920 ел), «*Азат хатын*» (1921), «*Эш таңы*» (1921 — 1922), «*Яшь йөрәк*»(1921 — 22) г-талары нәшер ителә. Хәзерге көндә «Мирас» татар иҗтимагый үзәге (1990 нан), Башкортстан татар конгрессы бүлеге (1997 дән), Татар яшьләре берлеге ф-лы эшли. 2006 да Казанда үткәрелгән конкурста Эстәрлетамак пед. көллиятенең татар бүлеге (1991 дән) һәм Эстәрлетамак пед. академиясенең филол. ф-ты (1993 тән) РФ махсус урта һәм югары уку йортларының татар бүлекләре арасында җиңүче булып танылa. Пед. академиядә «Фикер» студентлар г-тасына татарча кушымта нәшер ителә; 1997 дә татар һәм чуаш филологиясе кафедрасы оештырыла. 1995, 1998, 2003 тә «Татар теле һәм әдәбиятын укытуның актуаль мәсьәләләре» бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе, 2008 дә тел галиме М.З.Зәкиевнең 80 яшьлек юбилеена һәм татар, чуаш филологиясе кафедраларының 10 еллыгына багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция уздырыла. 2004/05 уку елында Э.ның 31 мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Э.та тарих фән. д-ры М.И.*Абдуллин*, техник фән. д-ры Г.Г.*Вахитов*, икътисад фән. д-ры А.Ш.*Хәсәнова*, балет артисты Л.К.*Мөсәвәрова*, библиограф, журналист И.Г.*Рәмиев* туган.

**ЭСТӘРЛЕТАМА́К РАЙОНЫ́**, БРның көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 2221,6 *км*². Үзәге — Эстәрлетамак шәһәре (Уфадан 130 *км* көньяктарак). Халкы — 42281 кеше (2017). Татарлар саны: 1979 да — 7349, 1989 да — 8946, 2002 дә — 8138, 2010 да — 9329 кеше. Районда 112 торак пункты, ш.и. 14 татар, 11 рус-татар, 1 татар-чуаш, 1 мордва-татар авылы исәпләнә. Иң зур татар авыллары: Бүреказган (2015 тә — 902 кеше, татарлар — 80%), Үрге Усылы (756), Талач (713), Кырмыскалы (503). Татар мәдәнияте үзәге — Бүреказган мәдәният йорты. Э.р.нда Башкортстан татарлары конгрессы бүлекчәсе (1995 тән), район татарларының милли-мәдәни үзәге (Бүреказган а.) эшли. «Миләш» халык бию ансамбле (1972 дән), «Яшь йөрәкләр» татар җыры халык фольклор ансамбле (1986 дан), «Тулпар» үрнәк бию ансамбле (Бүреказган а., 2002 дән), «Ядкәр» татар җыры халык ансамбле (Рощинский а., 1997 дән), «Гүзәл» халык ансамбле (Загородный а., 1998 дән), «Ахирәтләр» татар җыры халык фольклор ансамбле (Түбәнге Усылы а., 2005 тән) эшли. Районның 3 мәктәбендә укыту татар телендә бара, 2 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә (2015/16 уку елы). «Авыл тормышы» татар г-тасы нәшер ителә. Э.р.нда Сов. Союзы Герое Х.Б.*Әхтәмов*, Соц. Хезмәт Геройлары С.С.Әскәров, Р.Г.Баһаветдинов, М.З.Гайфуллин, М.С.Хәбибуллин; язучылар И.Н.*Насыйри* (Насыйров), А.К.Әһлиуллин, К.Я.Тукаев, шагыйрь Р.В.Жданов туган. Сов. Союзы Герое Д.С.*Ногманов*, Соц. Хезмәт Геройлары М.М.Фәйзуллин, Г.Р.Хисмәтуллинның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Э.р. б-н бәйле.

*Әд.:* А с ф а н д и я р о в А.З. История сёл и деревень Башкирской АССР: Справ. Уфа, 1990. Кн. 1; Стерлитамакский район Республики Башкортостан: Энцикл. Уфа, 2007.

**ЭСТО́НИЯ** (Эстония Респ-касы), Европаның төньягында урнашкан дәүләт. Мәйданы — 45226 *км*². Башкаласы — Таллин шәһәре. Халкы — 1319133 кеше (2018), ш.и. 2,5 меңләп татар. Татарлар, башлыча, Таллин, Ида-Вирумаа, Йыхви, Маарду, Нарва, Пярну, Тарту, Кохтла-Ярве шәһәрләрендә яшиләр. Алар Э. терр-ясендә 16 йөзнең 2 нче яртысында урнашалар, Ливон сугышында рус гаскәрләре составында катнашкан татарларның бер өлеше монда яшәп кала. 1700 — 21 еллардагы Төньяк сугышы тәмамлангач, Таллинда вакытлыча урнашкан Россия моряклары арасында татарлар күп була, шунлыктан шәһәр урамнарының берсе Татари (ягъни «Татар») исемен йөртә. Бу чорда Ласнамяэ шәһәрендә мөселман гыйбадәтханәсе эшли. 19 йөз уртасында, Э. терр-ясенә Түбән Новгород губернасыннан килгән татар сәүдәгәрләре урнаша башлагач, даими яшәүче татар диаспорасы формалаша. 20 йөз башында күп кенә шәһәрләрдә мөселман мәхәлләләре була. 1928 дә Э.дә ислам җәмгыяте (1940 та ябыла, 1994 тә кабат эшли башлый) теркәлә. Бөек Ватан сугышы чорында Э. татарларының бер өлеше Финляндиягә, Швециягә, Канада һәм Австралиягә күчеп китә. Сугыштан соңгы чорда Э. татарлары респ-кага килүче белгечләр (1950 елларда — Нарва ГЭСы һәм Маарду хим. комб-ты; 1970 еллар ахырында — Олимпия комплексы; тимер юл һәм порт төзелешләре) һәм хәрби хезмәткәрләр исәбенә арта. 1988 дә Маарду шәһәрендә Татар мәдәни оешмасы (соңрак Э. татар җәмгыяте булып теркәлә) төзелә. 1995 тән Таллинда Э. татарларының «Идел» мәдәни оешмасы эшли, аның әгъзалары мөселман бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр, Г.Тукай, М.Җәлил




Эстония. «Таллинда татар киносы көннәре» фестивале афишасы. 2012.

һ.б.ларга багышланган әдәби кичәләр үткәрәләр, мөселман зиратын карап торалар. Якшәмбе мәктәбендә татар теле һәм гарәп язмалары өйрәнелә; татар китапханәсе һәм татар хоры эшли. 2010 да Таллинда ТР Мәдәният министрлыгы һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты делегацияләре, Финляндия һәм Латвия татарлары катнашында «Идел» оешмасының 15 еллыгына багышланган юбилей чаралары үткәрелә. Юбилейга багышлап, «Эстония татарлары» күргәзмәсе, «Эстония татарлары: тарих, дин, мәдәният» халыкара конференциясе оештырыла, Татарстан артистлары чыгыш ясый. Э.дә «Йолдыз», «Алтын» татар оешмалары (Таллин), Нарва татар җәмгыяте, Нарва татар мәдәни оешмасы, Йыхви татар җәмгыяте, Г.Тукай исем. татар мәдәни оешмасы (Пярну), «Нур» (Тарту), Ида-Вирумаа татар җәмгыятьләре эшли. Татар җәмгыятьләре Э. Азчылыкны тәшкил итүче милләтләр ассоциациясе составына керә. Ел саен ТРның матди ярдәме б-н Сабан туе уздырыла. «Радио 4» радиостанциясендә эфирга «Серебряная нить» (Э.дәге азчылыкны тәшкил итүче милләтләр, ш.и. татарлар тормышына багышлана) һәм «Дуслык» (2011 дән, татар телендә) тапшырулары чыга. 2009 дан «Кояш» бәйсез татар яшьләр оешмасы эшли. 2010 да Таллинда «Turath» («Наследие») Э. мөселман мәдәни үзәге ачыла, ул җәйге лагерьлар оешты-

ра, дини бәйрәмнәр үткәрә, «As Salam» мөселман г-тасын нәшер итә. 2012 дә Таллинда Татар киносы көннәре, Нарвада Бөтенбалтыйк Сабан туе уздырыла.

*И.М.Әхмәт, Ф.Ф.Һадиуллина.*

**ЭСТРА́ДА МУ́ЗЫКАСЫ**, күңел ачуга корылган («җиңел») вокаль һәм инструменталь музыканың төрледән-төрле формаларын үз эченә ала. Татар Э.м.ның тамырлары 20 йөз башына барып тоташа һәм милли концертлар бирүче беренче буын башкаручылар (җырчылар К.Мотыйгый һәм Ф.Латыйпов, гармунчы Ф.Туишев, пианист З.Яруллин һ.б.) эшчәнлеге б-н бәйле. 1920 еллар уртасыннан татар концерт программалары репертуарында Г.Кайбицкая, Ф.Маннапов, С.Айдаров, С.Садыйкова һ.б. башкаруында С.Сәйдәшев әсәрләре урын ала башлый. Респ-када Э.м. үсешенә Татар филармониясе эшчәнлегенең йогынтысы зур була (1937 дән). Татарстанда музыка уен кораллары б-н башкарылучы Э.м.ның торгызылуына 1940 елларның 2 нче яртысы — 1950 елларның 1 нче яртысында Казанда эшләгән



«Үзгәреш җиле» татар җыры фестивале. Казан. 2018.

О.Лундстрем җитәкчелегендәге джаз-оркестр зур өлеш кертә. Аннан соңгы елларда Э.м. үсешенә В.Деринг җитәкчелегендәге ТР Дәүләт кинематография оркестры, Р.Үтәй җитәкчелегендәге ТР Дәүләт эстрада-симф. оркестры, соңрак А.Василевский җитәкчелегендәге ТР Филармония джаз-оркестры яңа



Россия телевидениесенең 1нче каналындагы «Тавыш» («Голос») музыкаль конкурс-тамашасының җиңүчеләре: Д.Гарипова һәм Э.Кәлимуллина.

этәргеч бирә. Татар эстрада концертында җыр жанрына өстенлек бирелә. Эстрада җырлары С.Садыйкова, Р.Яхин, А.Монасыйпов, Р.Еникиев, Ф.Әхмәтов, Р.Абдуллин, Л.Батыр-Болгари, Р.Ахиярова һ.б. композиторлар тарафыннан иҗат ителә. Милли җыр традицияләрен төрле елларда Г.Сөләйманова, Р.Ваһапов, З.Басыйрова, Ә.Авзалова, И.Шакиров, Г.Рәхимкулов, Ф.Сөләйманова, Г.Ильясов, Ш.Әхмәтҗанов, Э.Җәләлетдинов, З.Сәхәбиева кебек танылган осталар үстерә. Хәзерге танылган татар эстрада җырчылары арасында С.Фәтхетдинов, А.Галимов, З.Билалов, З.Фәрхетдинова, Н.Нигъмәтуллин, Ф.Вәлиәхмәтов, И.Газиев, М.Сөнгатуллин, Д.Нигъмәтуллина, Ф.Мортазин, Г.Сафин, Р.Галимова һ.б. бар. Фәридә–Алсу дуэты, «Айфара», «Зө-Ләй-Лә», «Казан егетләре», «Болгар кызлары» һ.б. вокаль һәм вокаль-инструменталь төркемнәр яшьләр арасында зур популярлык казана. Җырчылар А.Әсәдуллин, Р.Ибраһимов, Алсу, З.Камалова, Д.Бәдретдин, «Бәхет» вокаль-инструменталь ансамбле респ-кадан читтәге төбәкләрдә концерт эшчәнлеге алып бара. Татар Э.м.нда хәзерге массакүләм музыканың төрле стиль юнәлешләре бар. Аның инфраструктурасына FM-радиостанцияләр, продюсерлык үзәкләре (студия аудиоязмаларын чыгару, җырларга видеоклиплар төшерү) керә.




Халыкара «Татар җыры» эстрада җырлары фестиваленең ябылу тантанасы. Казан. 2012.

«Татар җыры», «Үзгәреш җиле», Р.Ваһапов исем. Халыкара татар җыры фестивальләре уздырыла.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ЭТ БАЛЫКЛА́Р**, этләчләр(Cobitidae), карпсыманнар отрядыннан балыклар семьялыгы. Дөнья фаунасында 150 дән артык төре билгеле. Евразия, Төньяк һәм Көнчыгыш Африканың төче суларында яши. ТР терр-ясендә 2 төре бар: эт балык (Misgurnus fossilis) һәм чәнечкеле балык (Cobitis taenia). Гәүдәсе озынча, 15 *см* га кадәр озынлыкта. Тәңкәсез яки бик вак тәңкәчекләр б-н капланган. Авыз тирәсендә 6–12 мыкчыгы бар. Йоткылык тешләре бер рәтле. Балык куыгының алгы өлеше сөяк капсула эчендә. Эт балык барлык агымсыз һәм ләмләнгән тугай сулыкларында, үлән б-н капланган сай сулы күлләрдә очрый. Кислородка ярлы тискәре шартларны җиңел кичерә. Чәнечкеле балык төбе ташлы һәм комлы булган агымлы сулыкларда яши. Һәр ягыннан күзләре астында җыелмалы чәнечке бар. Гәүдәсенең ян-ягы кара таплы. Э.б. су төбендәге организмнар б-н туклана. Уылдыгын язын, үсемлекләргә сала. Кәсәбәчелек әһәмияте юк.

**ЭТ БОРЧАГЫ́**, мальва (Malva), тырнакгөлчәләр семьялыгыннан бер-, ике яки күпьеллык үләнчел, сирәк кенә ярымкуакчыл үсемлекләр ыругы. Якынча 40 лап төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача, ара-тирә субтропик поясларында таралганнар. ТР терр-ясендә 5 төре бар. Билгесез Э.б. (M. neglecta), яткын Э. б. (M. pusilla) барлык районнарда; бөдрә Э.б. (M. crispa), мавритан Э.б. (M. mauritiana), урман Э.б. (M.sylvestris) — Көнбатыш Кама алдында очрый. Буш урыннарда, юл буйларында, торак пунктларда, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчаларында үсәләр. 8 дән 120 *см* га кадәр биеклектәге берһәм күпьеллык үсемлекләр. Яфраклары чиратлашкан, түгәрәк-йөрәксыман формада. Чәчәкләре эре, алсу, тыгыз йомгакчыклар булып яфрак куентыкларына җыйналган яки чук чәчәк төркеме хасил итә. Җимеше коры, күп сандагы бер орлыклы җимеш-орлыкчаларга таркала. Июнь-сентябрьдә чәчәк аталар. Җимешләре июль-октябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Яфракларында һәм чәчәкләрендә лайла, флавоноид, органик к-талар, каротин бар. Халык медицинасында Э.б. яфраклары һәм чәчәкләреннән ясалган төнәтмәсе ашказаны-эчәк тракты һәм сулыш юллары ялкынсынганда, тире авырулары вакытында кулланыла. Барлык төрләре дә — терлек азыгы. Баллы үсемлекләр.

**ЭТ СЫРГАНАГЫ́** (Bidens), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 230 дан артык төре билгеле, бөтен Җир шарында, күбесенчә Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә 6 төре бар. Иенке Э.с. (B. cernua) һәм өч җаймәле (B. tripartita) бөтен җирдә очрыйлар, икешәр каурыйсыман Э.с. (дваждыперистая) (B. bipinnata), яфраклы (олиственная) Э.с. (B. frondosa), гибрид (кушылгак) Э.с. (B. garumnae), нурлы (лучевая) Э.с. (B. radiata) — сирәк төрләр. Елга, сазлык һәм

күл буйларында, су баса торган болыннарда, чәчүлекләрдә, тимер юл өемнәре буенда үсә. 15–100 *см* биеклектәге берьеллык үсемлек. Сабагы туры, ботаклы. Яфраклары каршыдаш, бөтен яки бүленмә. Чәчәкләре тонык сары, бүрәнкәсыман-көпшәле, кәрзиннәрдә урнашкан. Җимеше — орлыкча. Июль-августта чәчәк аталар. Җимешләре июль-сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Нурлы Э.с., иенке Э.с. һәм өч җәймәле Э.с. составында флавоноид, дуплау матдәләре, микроэлементлар, эфир майлары бар. Халык медицинасында үсемлек төнәтмәсе бәвел кудыру һәм тир чыгару чарасы буларак , ш.у. дәвалау ванналары ясауда кулланыла. Барлык төрләре дә баллы.

**ЭТ ТИГӘНӘГЕ́** (Xanthium), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 25 ләп төре бар, бөтен Җир шарында диярлек таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — гади Э.т. (X.strumarium) бар. Чүп үләне буларак буш урыннарда, чәчүлекләрдә һәм бакчаларда, елга ярлары буенда үсә. 30–100 *см* биеклектәге, соргылт-яшел үсемлек. Сабагы ботаклы. Яфраклары чиратлашкан, калаксыман, озын сапларда. Чәчәк төркеме бер җенесле; ата чәчәкләр — күп чәчәклеләр, бер рәтле тар яфраклардан торучы тышчалы шарсыман; ана чәчәкләр — ике чәчәклеләр, сибелеп утырган чәнечкеләр б-н капланган. Җимеше — озынча түгәрәк орлыкча. Июль-августта чәчәк ата. Үсемлекнең барлык өлешләрендә флавоноид, алкалоид, аскорбин к-тасы, йод, орлыкларында — сумала, сапонин, 40% ка кадәр май бар. Халык медицинасында үләне согы кычыткан бизгәге, экзема, төче авыруы вакытында кулланыла. Баллы үсемлек.

**ЭТ ШОМЫРТЫ́** (Frangula), эт шомыртычалар семьялыгыннан куаклар яки зур булмаган агачлар ыругы. Якынча 50 ләп төре билгеле, Евразиянең уртача поясында, Төньяк Америкада һәм Төньяк Африкада таралганнар. Россиядә бер төре — мурт Э.ш. (зирексыман кошкунмас) (F. alnus) бар. ТР терр-ясендә барлык районнарда очрый. Яфраклы һәм



Зирексыман кошкунмас.

ылыслы урманнарда, елга һәм күл буйларында, ш.у. ерымнарда үсә. 1,5–4 *м* биеклектәге куаклык. Яшь ботакларының кабыгы шома, ялтыравыклы, кызыл-көрән, ак ясмыкчыклар б-н капланган, карт ботаклары — кара диярлек соргылт-коңгырт төстә, тонык ясмыкчыклы. Яфраклары чиратлашкан, озынча-эллипссыман, өске ягы кара яшел, ялтыравыклы, аскы ягы саргылт-яшел, кайвакыт сеңерләре кызыл-көрән төкчәле. Чәчәкләре вак, аксыл, күрексез, 2–7 булып яфрак куентыгында урнашканнар. Җимеше — йомыркасыман өч төшле шарсыман сусыл төшчә (башта алсу-кызыл, соңыннан шәмәхә-кара). Май-июньдә чәчәк ата. Җимешләре август-сентябрьдә өлгерә. Вегетатив юл б-н — тамыр үрентеләре, төп үсентеләреннән, ш.у. орлыклардан үрчи. Дару үсемлеге. Составында гликозид, флавоноид, пектин матдәләре, органик к-талар, лайлалар булган җимешләре кулланыла. Э.ш.ыннан ясалган дарулар эч йомшарткыч, җәрәхәтләрне төзәтү һәм бактерицид үзлекләргә ия. Бакча һәм паркларда үстерелә, табигый киртәләр булдыруда файдаланыла. Үзагачы йомшак, кызгылт-сары төстә, вак агач эшләнмәләре ясауда кулланыла. Баллы үсемлек.

**ЭТ ЭЧӘГЕСЕ́**, уралма сабаклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр төре, чүп үлән. Татарстан терр-ясендә чәчүлекләрдә, бакчаларда, юл кырыйларында, коймa буйларында үсә. Тамыр үрентеләреннән һәм орлыклардан үрчи (бер үсемлек туфракта үзенең яшәү сәләтен 3 ел саклый ала торган 400–600 орлык бирә). Э.э. сабаклары б-н игеннәргә урала, аларны сөрлегүгә китерә. Чәчүлекләрнең чүпләнүе уңышны 30–50% ка киметергә мөмкин. Э.э.н тамырдан бетерү бик кыен. Аны бетерү өчен туфракны системалы эшкәртү кулланыла: катламнарны әйләндереп йомшарту, тирән итеп тунга сөрү, ш.у. химик көрәш чаралары (ике өлешле үсемлекләргә каршы гербицидлар). Яшел азык буларак терлекләргә күп ашатканда агулы, печән буларак зарарсыз.



*Әд.:* Тахтаджян А.Л. Система и филогения цветковых растений. М.-Л., 1966.

**ЭТИМОЛО́ГИЯ** (грекчадан étymon — хакыйкать, сүзнең төп мәгънәсе һәм *...логия*), 1) сүзнең яки морфеманың килеп чыгышы; 2) тел белеменең бер тармагы; сүзләрнең, морфемаларның килеп чыгу тарихын өйрәнә һәм сүзнең иң борынгы мәгънәләрен ачыклау б-н шөгыльләнә. Э. фонетика, морфология һәм сүзләр семантикасының тарихи үзгәрү закончалыкларына нигезләнә, шул ук вакытта башка фәннәргә, беренче чиратта тарих һәм этнография мәгълүматларына мөрәҗәгать итә. Төрле тел берәмлекләрен, структур элементларны, сүзләрнең мәгънәләрен һ.б.ны чагыштырма-тарихи ысул б-н өйрәнү этимологик анализның нигезен тәшкил итә. Татар тел белемендә Э. мөстәкыйль юнәлеш буларак 20 йөзнең 2 нче яртысында Р.Г.*Әхмәтьянов* һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә формалаша. Аларның тырышлыклары нәтиҗәсендә күп кенә тел күренешләренә яңача караш барлыкка килә; мәс., «Казан» топонимы күп еллар дәвамында «казан» сүзе б-н бәйле була. Этимологлар, рус елъязмаларында очрый торган «кусян» топонимына игътибар биреп, шундый нәтиҗәгә киләләр: «ку» структур элементы «якты, ак» мәгънәсен белдерә, ә «сян/сюн» «хуннар», ягъни «ак хуннар шәһәре» этнонимына туры килә. Э. тарафыннан -лы/-ле аффиксының өйрәнелүе «Әлмәт» топонимының асылын ачарга ярдәм итә. Аңарда аффиксның -ты/-т борынгы формасы ныгып калган: әлмә(элмә)+т, ягъни әлмәт — элмә агачына бай.

Татар. Э.сенең хәзерге үсеш дәрәҗәсе Р.Г.Әхмәтьяновның этимологик сүзлекләрендә («Татар теленең этимологик сүзлеге», 1–2 т., Бөре, 2005–07) каралган.

*Әд.:* Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. К., 2001; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998; Закиев М.З. Происхождение тюрков и татар. М., 2003.

*М.З.Зәкиев.*

**Э́ТНИК МУ́ЗЫКА ГЫЙЛЕМЕ́**, халык музыкасын өйрәнүче фәнни дисциплина. Ул ш.у. чагыштырма музыка гыйлеме, муз. этнография, муз. фольклористика буларак та билгеле. Э.м.г.нең төп предметы — муз. фольклор үрнәкләрен җыю һәм аларны өйрәнү. Татар халык музыкасы үрнәкләрен җыю һәм бастыру тарихы якынча 200 елны үз эченә ала. Бу эшчәнлектә 3 чорны аерып карарга мөмкин. Беренче (аеруча элгәреге) чор рус тикшеренүчеләре тарафыннан «әҗнәбиләр»нең матди һәм рухи мәдәниятенә карата фәкать этнографик кызыксынулары б-н аерылып тора (19 йөз этнограф-музыкантлары И.Добровольский, С.Рыбаков, В.Мошков хезмәтләре). Икенче чор фонограф куллану б-н билгеләнә. Моңа Казан ун-ты каршындагы В.Богородицкий оештырган һәм җитәкләгән Экспериментальфонетика кабинеты (20 йөз башы) этәргеч бирә. Ноталарны транскрипцияләү б-н «Сигез татар-башкорт җыры» («Восемь татарско-башкирских песен», 1923) җыентыгын басмага әзерләгән М.Берг шөгыльләнә. Фонографик язмалар Беренче бөтендөнья сугышы елларында татар хәрби әсирләреннән татар халык көйләрен язып алган немец тикшеренүчеләре Г.Шюнеман һәм Р.Лахның татар фольклоры үрнәкләре басмаларының нигезен тәшкил итә. Курайда уйнау өчен «Башкорт һәм татар көйләре» («Башкирские и татарские мотивы», 1916) җыентыгын бастырган Саратов консерваториясе профессоры М.Солтанов һәм 80 елдан соң Г.Макаров наширлегендә дөнья күргән «Милли моңнар. Төрки-татар көйләре» («Национальные мелодии. Тюрко-татарские напевы», 2002) җыентыгы авторы комп. С.Габәши татар Э.м.г.нә сизелерлек өлеш кертәләр. Татар халык көйләренең беренче күләмле җыентыгын комп. А.Ключарёв («Татар халык җырлары» — «Татарские народные песни», 1941, В.Виноградов һәм М.Садри б-н берлектә) бастырып чыгара. Җырларны җыю-туплау эшчәнлегенең өченче чоры (20 йөзнең 2 нче яртысы) үзенчәлекле күтәрелеш кичерү б-н характерлана. Аңа Татарстанда проф. музыка сәнгатенең уңышлы үсеше төп сәбәпче була. Муз. фольк-

лор җыентыкларын композиторлар М.Мозаффаров (1964 тә) һәм Җ.Фәйзи (1971 дә, заманча көйләр) нәшер итә. 1970 еллардан фольклор җыентыклары чыгару башлана, авторлары — проф. этник музыка белгечләре М.Нигъмәтҗанов, Р.Исхакова-Вамба, З.Сәйдәшева. 1970 еллар ахырыннан татарларның муз. фольклоры Казан консерваториясе студентларының Ш.Шәрифуллин, З.Сәйдәшева, Г.Макаров җитәкчелегендәге системалы фольклор-этнографик экспедицияләре объекты була. Татар халык музыкасы үрнәкләре 20–21 йөзләр чигендә актив басыла. Муз. фольклорның капма-каршы өлкәләренә — бик борынгы җырларга һәм хәзерге җыр лирикасына кызыксыну уяну күзәтелә. Беренче юнәлеш композиторлар Ш.Шәрифуллин, К.Хөснуллинның татар-мөселман көйләре һәм этник музыка белгече Н.Әлмиеваның борынгы керәшен татарлар җырлары тупланган җыр җыентыкларында тормышка ашырыла. Заманча җыр лирикасына З.Сәйдәшева кызыксыну күрсәтә.

Фольклор үрнәкләрен җыю б-н беррәттән Казан ун-ты ачылу (1804) б-н бәйле рәвештә Э.м.г.н фән буларак формалаштыру эше алып барыла. Татар Э.м.г. үсеше өчен 1878 дә ун-т каршында *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* оештырылу аеруча зур әһәмияткә ия була. Татар Э.м.г.ндә тикшеренү эшләре өч юнәлештә алып барыла. Беренчесенә (аеруча башлангыч чорга караганына) татарларның (мөселманнарның һәм керәшеннәрнең) көнкүреш музыкасын тасвирлау б-н бәйле этнографик күзәтүләр, ш.у. Казан ун-ты профессорлары К.Фукс, Н.Катанов, В.Мошков, С.Рыбаков, православие миссионеры В.Витевский, татар мәгърифәтчесе К.Насыйри тарафыннан көй б-н башкарыла торган жанрларның текстларын нәшер итү керә. Икенче юнәлеш — татар муз. фольклоры жанрларын билгеләү һәм системага салу (С.Рыбаков, М.Нигъмәтҗанов, Р.Исхакова-Вамба, Ә.Абдуллин, З.Сәйдәшева, Н.Әлмиева, Э.Каюмова), өченче татар муз. фольклорының лад төзелеше (И.Козлов, Я.Гиршман, М.Нигъмәтҗанов, З.Сәйдәшева, Л.Бражник), ритмика (Е.Смирнова) үзенчәлекләрен тикшерү б-н бәйле.

*Әд.:* Нигмедзянов М.Н. Татарская народная музыка. К., 2003; Сайдашева З.Н. Татарская музыкальная этнография. К., 2007.

*З.Н.Сәйдәшева.*

**ЭТНОГРА́ФИЯ** (грек. éthnos — кабилә, халык һәм ...*графия*), халыкларны (этносларны) һ.б. этник бергәлекләрне, аларның килеп чыгышын, таралышын, көнкүрешен һәм мәдәни-тарихи мөнәсәбәтләрен өйрәнүче фән. Э. предметының нигезен аның этник йөзен билгеләүче халык мәдәнияте тәшкил итә. Этнографик мәгълүматларның зур өлеше халык тормышын турыдан-туры күзәтү (стационар һәм экспедицияләр вакытында тикшеренүләр, коллекцияләр туплау һ.б.), анкеталар тутыру һәм социол. сораштыру алымнары ярдәмендә туплана. Э. эргәдәш фәннәр — гуманитар (антропология, тарих, социология һ.б.) һәм табигыять (география, икътисад һ.б.) фәннәре мәгълүматларын кулланып, тикшерү предметына комплекслы якын килүгә нигезләнә.

Казан төбәге Э.се турындагы беренче җентекле мәгълүматлар *академия экспедицияләрендә* (18 йөзнең 2 нче яртысы) катнашучылар — И.И.*Георги*, И.И.*Лепёхин*, П.С.*Паллас* хезмәтләрендә очрый. Аларда Урта Идел буе һәм Урал алды халыклары: татар, башкорт, мордва, чуаш һ.б. мәдәниятенә, көнкүрешенә һәм йолаларына шактый урын бирелә. Россиядә Э. фән буларак 19 йөздә формалаша. 1804 елда Казан ун-ты ачыла, анда Э. мәсьәләләре б-н Россия дәүләте тарихы, статистикасы һәм географиясе каф. һәм *Шәрекъ бүлеге* галимнәре И.Н.*Березин*, А.К.*Казимбәк*, О.М.*Ковалевский* һ.б. шөгыльләнә. Алар төбәк, Себер, Ерак Көнчыгыш һәм кайбер чит ил халыкларының мәдәни-көнкүреш һәм тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә зур өлеш кертәләр. 1815 тә ун-т каршында сирәк табылдыклар кабинеты оештырыла, аның беренче экспонатлары ун-т галимнәре тарафыннан Шәрекъкә (Тын океан утраулары, Кытай, Монголия) һәм Урта Идел буена оештырылган экспедицияләр вакытында табылган халык көнкүреше предметларыннан (хезмәт кораллары, кием-салым, бизәнү әйберләре һ.б.) гыйбарәт була (к. *Казан университетының Этнография музее*).

Казан татарларының мәдәниятен һәм көнкүрешен башлап өйрәнүчеләрнең берсе булып Казан ун-ты профессоры К.Ф.*Фукс* исәпләнә. Аның хезмәтләрендә ш.у. Казан татарлары турында стат. мәгълүматлар китерелә, аларның руслар б-н үзара мөнәсәбәтләре тасвирлана һ.б. Алардан һәм ш.у. А.А.*Фукс*, М.С.*Рыбушкин*, В.С.Сбоев һ.б. хезмәтләреннән Казан төбәге халыклары Э.сенең фән буларак формалашуы башлана. 19 йөзнең 2 нче яртысында татар интеллигенциясе вәкилләре — Ш.*Мәрҗани*, К.*Насыйри* һ.б. хезмәтләре барлыкка килә, аларда Казан татарларының традицион мәдәнияте буенча бай этнографик материал туплап бирелә. 1878 дә Казан ун-ты каршында *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* оештырыла, аның җитәкчеләре һәм әгъзалары Г.Н.*Әхмәров*, Н.Ф.*Катанов*, И.Н.*Смирнов*, Н.А.*Фирсов*, П.Д.*Шестаков* һ.б. була; 1884 тә геогр. һәм Э. каф. ачыла. Системалы рәвештә этнограф белгечләр әзерләү башлана, экспедицияләр оештырыла. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Казан төбәге Э.се үсешенә этнограф, музей белгече, Казан ун-тының геогр., Э. һәм антропология каф. мөдире (1911–23) Б.Ф.Адлер зур өлеш кертә, ул Урта Идел буен һәм Татарстан АССРны геогр. һәм этнографик яктан өйрәнүнең төп бурычларын билгели. Аның тәкъдиме б-н Казан ун-ты каршында Археол. һәм Э. музее (1913) оештырыла.

1920 еллар башында төп этнографик тикшеренүләр ТАССР Үзәк музее тарафыннан гамәлгә ашырыла, Б.Ф.Адлер шәкерте Н.И.Воробьёв аның директоры (1930 га кадәр) булып тора. Ул татар һәм чуаш халыкларының мәдәниятен һәм көнкүрешен өйрәнү буенча интенсив эшчәнлек җәелдереп җибәрә; аның катнашында ТАССРның барлык районнарына диярлек экспедицияләр оештырыла. Н.И.Воробьёв тарафыннан тупланган бай этнографик материал «Казан татарларының матди мәдәнияте» («Материальная культура Казанских татар», 1930) хезмәтендә урын ала, анда халыкның традицион мәдәнияте һәм йолалары тасвирлана, беренче тапкыр Казан татарларының килеп чыгышы турындагы мәсьәлә күтәрелә. Казанда башка этнографларның да Урта Идел буе халыкларын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре — М.Е.Евсевьевның «Татреспублика мордвалары» («Мордва Татреспублики», 1925), М.С. һәм Г.С.Гобәйдуллиннарның «Казан татарларының аш-суы» («Пища Казанских татар», 1927), В.В.Егеревның «Казан төбәге халыкларының үзенчәлекле таралышы» («Самобытное расселение народностей Казанского края», 1928) һ.б. басыла. Респ-када этнографик тикшеренүләр үсешенә төбәкне өйрәнү хәрәкәте зур өлеш кертә (к. *Төбәкчелек белеме*). Этнографик тикшеренүләрне координацияләүдә *Академүзәк*, *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте*, *Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы* һ.б. мөһим роль уйный. Әлеге оешмаларның җитәкчеләре һәм әгъзалары — күренекле галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләре Г.С.*Гобәйдуллин*, Г.Г.*Ибраһимов*, Гали *Рәхим*, М.Г.*Худяков* һ.б. була. Алар татар теле һәм әдәбиятын, Урта Идел буе халыкларының тарихын һәм Э. сен өйрәнү б-н шөгыльләнәләр. 1920 еллар уртасында бу оешмалар татар халкының көнкүреше, йолалары һәм мәдәнияте буенча тикшеренүләр өчен даими рәвештә этнографик экспедицияләр уздыралар.

1920 еллар ахырында илдәге гуманитар фәндә кризис башлануга бәйле рәвештә төбәктә Э. үсеше кискен акрыная. Моңа Совет хөкүмәтенең милләтләрне якынайтуга, кешеләрнең яңа, этник булмаган бергәлекләрен формалаштыруга һ.б. юнәлтелгән сәясәте дә сәбәпче була. Милли мәдәниятне һәм традицияләрне өйрәнүгә омтылыш милләтчелек чагылышы дип бәяләнә. 1930 елларда этнографик тикшеренүләр һәм экспедицияләр оештыру б-н шөгыльләнгән күп кенә үзәкләр бетерелә.

1930 еллар ахырында Э.нең фән буларак яңарышы башлана. Татарстан халыкларының Э.сен тикшерү буенча Татарстан Тел, әдәбият фәнни-тикшеренү ин-ты (1941 дән Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү ин-ты, 1945 тән СССР ФАнең Казан ф-лы составында, 1997 дән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты) төп үзәккә әверелә. Бөек Ватан сугышыннан соң Казан ун-ты этнографик тикшеренү эшләрен яңартып җибәрә, 1946 да ул, СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты б-н берлектә, ТАССРның Кама арьягы р-ннарына экспедицияләр оештыра. Экспедициядә катнашучылар Урта Идел буенда яшәүче русларның традицияләре һәм көнкүреше, татар эпиграфикасы һ.б. буенча бай материал туплыйлар. 1940 еллар ахырында төбәктәге татар, чуаш, удмурт һ.б. халыкларны тарихи-этнографик яктан өйрәнү киң колач ала. Этнографларның күпьеллык өйрәнүләре нәтиҗәсе булып Н.И.Воробьёвның «Казан татарла-

ры (Октябрьгә кадәрге чордагы матди мәдәният буенча этнографик тикшеренүләр)» («Казанские татары (этнографические исследования материальной культуры дооктябрьского периода)», 1953) һәм Ф.Х.*Вәлиев*, Н.И.Воробьёв, Р.Г.*Мөхәммәдова* һ.б.ның «Урта Идел һәм Урал буе татарлары» («Татары Среднего Поволжья и Приуралья», М., 1967) коллектив хезмәте тора, аларда татар халкының тарихы һәм Э.сенең иң әһәмиятле яклары (килеп чыгышы, исәбе, урнашуы һ.б.) яктыртыла.

1960 еллардан Казан ун-ты этнографлары Урта Идел буе халыкларының гаилә һәм гаилә мөнәсәбәтләрен тикшерүгә керешәләр. Е.П.*Бусыгин* 16 йөз — 20 йөз уртасы рус авылы гаиләсен анализлый. 1970 — 2000 елларда ТР ФА нең Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты этнографлары татар халкының традицион мәдәнияте барлыкка килүе һәм үсешенең фундаменталь проблемаларын өйрәнәләр. «Татар халкының тарихи-этнографик атласы»н төзү кысаларында 30 дан артык экспедиция оештырыла, татарлар тупланып яшәгән төбәкләр (500 гә якын торак пункт) тикшерелә һәм күп кенә монографияләр: Н.А.*Халиковның* «Идел буе һәм Урал татарларының хуҗалыгы (XIX йөз уртасы — XX йөз башы)» («Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX вв.)», 1995); С.В.*Суслова*, Р.Г.Мөхәммәдованың «Идел буе һәм Урал татарларының милли киеме (XIX йөз уртасы — XX йөз башы)» («Народный костюм татар Поволжья и Урала (середина XIX — начала XX вв.)», 2000); «Татарларның этнотерриториаль төркемнәре һәм аларның формалашуы мәсьәләләре» («Этнотерриториальные группы татар и вопросы их формирования», 2002) басылып чыга. Әлеге юнәлеш үсеш алу б-н бәйле рәвештә, татарларның аерым төркемнәренә багышланган хезмәтләр: Р.Г.Мөхәммәдованың «Мишәр татарлар» («Татары-мишари», М.,1972), Ф.Л.Шәрифуллинаның «Касыйм татарлары» («Касимовские татары», 1992), Д.М.*Исхаковның* «Әстерхан татарлары» («Астраханские татары», 1992), «Мәлки керәшеннәре» («Молькеевские кряшены», 1993), Ф.Т.*Вәлиевнең* «Себер татарлары» («Сибирские татары», 1993), Е.П.Бусыгин, Н.В.*Зорин*, Р.Н.Мусина, Ф.Ш.*Сафина*, Г.Р.*Столярова*, С.В.Суслова, Р.К.*Уразманова* һ.б. ның этнографик хезмәтләре нәшер ителә.

1980 еллар ахырында — 1990 еллар башында Э. б-н кызыксыну сизелерлек арта. 1987 дә Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1996 дан ТР ФАнең Тарих ин-ты) этнология бүлеге оештырыла; 1988 дә Казан ун-тында археол. һәм Э. кафедрасы ачыла. Хәзерге җәмгыятьтә этник асылның актуаль социаль проблемалары: модернизация процесслары йогынтысы, бердәйлек формалары, көнкүрештә һәм этник үзаң структурасында дин, этносара мөнәсәбәтләр, ТРда иммигрантларның җайлашуы һ.б. тикшеренүчеләрнең аерым игътибарын җәлеп итә. Урта Идел буе халыкларының мәдәниятен, көнкүрешен һәм традицияләрен өйрәнү буенча тикшеренүләр дәвам итә: төбәк халыклары Э. се буенча күпсанлы мәгълүматлар «Татарлар» («Татары», М., 2001) һәм «Tartarica атласы. Татарлар һәм Евразия халыклары тарихлары. Татарстан Республикасы кичә һәм бүген» («Атлас Tartarica. Истории татар и народов Евразии. Республика Татарстан вчера и сегодня», М., 2006) коллектив монографияләрендә, күптомлы «Татар энциклопедиясе»ндә, «Борынгы заманнардан татарлар тарихы»нда («История татар с древнейших времён») урын ала.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. К.Ф.Фукс — первый исследователь быта Казанских татар // Вестн. Науч. об-ва татароведения. К., 1927. № 6; Бусыгин Е.П., Зорин Н.В. Русские коллекции в этнографическом музее Казанского университета // Советская этнография. 1958. № 5; шулар ук. Этнография в Казанском университете. К.,2002; Бусыгин Е.П. Основы этнологии: Курс лекций для студентов исторических факультетов. К.,2001.

*Р.Р.Батыршин.*

**ЭТНОНИ́МИКА** (грекча éthnos — кабилә, кавем, халык һәм óпута — исем, атама), *ономастиканың* ыруг, кабилә, кабилә берлекләре, халыклар, милләтләр һ.б. этник берлекләрнең — этнонимнарның килеп чыгышын, таралышын, функцияләрен һәм аталыш структурасын өйрәнүче тармагы.

Макроэтнонимнар — зур этнослар яки этник бергәлекләрнең (татарлар, башкортлар) атамалары һәм микроэтнонимнар — зур булмаган этник төркемнәр, кабилә атамалары (керәшеннәр, мишәрләр, типтәрләр) аерып өйрәнелә. Этнонимнар составында автоэтнонимнарны — халыкларның һәм кабиләләрнең үзатамаларын һәм аллоэтнонимнарны — аларга башка халыклар биргән исемнәрне аерып карыйлар. Автоэтнонимнар, гадәттә, «кеше», «ир-ат» төшенчәләре б-н бәйле. Төрки телләрдә ул — «ир» («ар», «ә(э)р»). Күпчелек автоэтнонимнар аңа төрле аергычлар өстәлеп ясала: суар (су-э(и)р) — су кешесе, сарир (сары-ир) — аксыл сары кеше, акацир (акац-ир) — урман кешесе һ.б. Аллоэтнонимнар еш кына бер халык вәкилләрен терр. яктан аеруча якын урнашкан кабилә исеме б-н атау традициясен дәвам итә; мәс., марилар барлык болгарларны да — суаслар, руслар кайбер очракларда аслар (яслар) дип йөртәләр. Кагыйдә буларак, этнонимнар теге яки бу этнос яшәгән ил яки өлкә б-н тиңләп карала. Туры тәңгәллек очрагында илнең исеме — этнонимнан (татарлар — Татарстан, греклар — Греция, чехлар — Чехия), кире тәңгәллек очрагында исә этноним ил(нең) исеменнән ясала (Америка — америкалы, Украина — украин). Мондый этнонимнар этнотопонимнар дип атала. Төрле топонимнардан ясалган атамалар этнонимнарга якын тора. Алар арасында гаять зур төбәкләрнең (хоронимнар) атамаларыннан (Европа — европалылар, Себер — себерлеләр) яки зур һәм кечкенә авылларның исемнәреннән (Казан — казанлылар, Бөгелмә — бөгелмәлеләр һ.б.) ясалган, ш.у. бер төркем халыкларның тарихтан килгән, рәсми булмаган кушаматлы атамаларыннан (казакълар, москальләр, чалдоннар һ.б.) торган этнохоронимнар бар. Этнонимнар б-н туры килгән атамаларның аерым бер өлешен лингвонимнар, ягъни теге яки бу этник берәмлекләргә караган телләр яки диалектларның атамалары тәшкил итә. Лингвонимнарның түбәндәге төрләрен аерып өйрәнәләр: 1) тел макросемьялыкларының атамалары (Урал-Алтай телләре, Алтай телләре); 2) тел төркемнәренең атамалары (төрки телләр, славян телләре); 3) нигездә этнонимнар б-н туры килгән телләрнең атамалары (татар, башкорт, мари һ.б.); 4) диалект төркемнәре яки диалект атамалары (нократ сөйләше, мишәр диалекты һ.б.). Аерым телләрнең яки диалектларның атамалары, кагыйдә буларак, этнонимнар яки этнотопонимнар б-н туры китерелә.

Этнонимнар дөнья халыклары тарихын, телләр үсешенең борынгы этапларын, төрле чорларда халыкларның таралыш үзенчәлекләрен һәм үзара мөнәсәбәтләрен өйрәнү өчен мәгълүматларга бай. Атамаларыннан башка берни дә, ягъни ни телләре, ни матди мәдәниятләре (мәс., кырым татарлары б-н кушылган таврлар) турында бернәрсә дә сакланмаган, югалган халыклар хакында нинди дә булса мәгълүмат җыйганда Э. күрсәткечләре аерым кыйммәткә ия була.

Тел галимнәреннән тыш тарихчылар, географлар, этнографлар да Э. өлкәсендә тикшеренүләр алып баралар. Э. этнография (этнология), ш.у. тарих һәм геогр. б-н тыгыз бәйләнештә үсеш ала.

*Әд.:* Зәкиев М.З. Этнонимиядән этногенезга // Төрки-татар этногенезы. М.-К., 1998; Аймуратов Д. Тюркские этнонимы. Нукус, 1986; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998.

*М.З.Зәкиев.*

**ЭФЕ́ДРА**, кызылтамыр (Ephedra), эфедрачалар семьялыгыннан ачыкорлыклы үсемлекләр ыругы. 40 тан артык төре билгеле, Евразиядә, Америкада, Төньяк Африкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — башаклы кызылтамыр яки Кузмичёв үләне (E. distachya) бар, Кама аръягында очрый. Балчыксыл һәм ташлы тау битләрендә үсә. 15–35 *см* биеклектәге мәңге яшел куакчык. Тамырчасы озын, шуышма. Сабагы буынтыклы. Яфраклары редукцияләшкән, коңгырт элпәле тәңкәчекләрдән тора. Чәчәкләре вак, берле, зур булмаган башакларга җыйналган. Җимеше — кызыл шарсыман ялган җиләк. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре җәй ахырында өлгерә. Орлыктан үрчи. Яшел ботакларында эфедрин алкалоиды (бронхиаль астма вакытында кулланыла), дуплау матдәләре, аскорбин к-тасы бар. Халык медицинасында төнәтмәсе ревматизм, ашкайнату органнары авырулары вакытында кулланыла. Э. табигый киртәләр булдыруда файдаланыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**«ЭФИ́Р»**, телекомпания. Оештыручысы — «Эфир» ҖЧҖ. 1991 елда Казанда радиотелетапшырулар станциясен төзү һәм эксплуатацияләү буенча кече пр-тие җирлегендә оеша. 1992 дә «Э.» телерадиотапшыруга лицензия ала; коллективның нигезен Казан телеүзәге һәм Казан ун-тының журналистика ф-ты хезмәткәрләре тәшкил итә. Беренче телетрансляция 1992 нең 8 июнендә була. 1990 елларда Казанның әйдәп баручы телекомпаниясе. 1994 тә «Э.» программаларын Әлмәт,

Бөгелмә, Зәй, Лениногорск, Түбән Кама, Чистай шәһәрләре кабул итә. Татар телендәге беренче «Адымнар» тапшыруы 1997 дә чыга башлый. 1998 дән тәүлек буе эшли. «Э.» — Халыкара радио- һәм телетапшырулар ассоциациясе һәм Бәйсез тапшырулар системасы әгъзасы, 1996 дан — Россия Милли телетапшырулар ассоциациясендә. Хәзер «Э.» Россиянең дәүләтнеке булмаган эре телекомпанияләр өчлегенә керә, Татарстанның мәгълүмат һәм реклама индустриясендә алдынгы урында тора. Үз тапшырулары челтәрендә — «Утро»(«Иртә») программасы (иртәнге канал), «Город»(«Шәһәр») мәгълүмати программасы (Казанның мәгълүмати мәйданы



«Эфир» телекомпаниясе бинасы. Казан.

лидеры), «Перехват» вакыйгалар хроникасы (каналның иң рейтинглы проектларының берсе), «Fam TV» хатын-кызлар программасы, «О.Р.З.» сәламәтлек турындагы программа һ.б. Телекомпания Бөтенроссия телевизион конкурслар: «Новости — время местное» («Яңалыклар — җирле вакыт», 2000, 2001), «ТЭФИ — регион» (2002, 2003, 2007) бүләкләре б-н бүләкләнә. 1998, 2000, 2005 һәм 2008 дә Россия телетапшырулар милли ассоциациясе тарафыннан «Э.» иң яхшы төбәк телекомпаниясе дип табыла. «Э.» ның челтәр партнёры — «РЕН-ТВ», аның тапшырулар челтәрендә «24» мәгълүмати программасы, нәфис фильмнар, телесериаллар, программа-цикллар, күңел ачу программалары, мультипликацион сериаллар чыгарыла. «Э.»ның төп аудиториясе — халыкның 25 тән 54 яшькәчә булган өлеше. «Эфир» ҖЧҖ директорлар советы рәисе — А.П.Григорьев, ген. директоры — Г.Ф.Яхина.

**ЭХИНОКО́КК**, тасма суалчан (Echinococcus granulosus), тасма суалчаннар семьялыгыннан. Эт, бүре, төлкеләр эчәклегендә паразитлык итә. Озынлыгы 3–6 *мм*. Гәүдәсе баштан (4 имгеч һәм 2 кармавычлы таҗчык) һәм 3–4 буынтыктан тора. Соңгысы — өлгергән буынтык, анда формалашкан күкәйләр б-н тулы аналык урнашкан. Тереклек циклы катлаулы, арадаш хуҗалар тезмәсе киң, кеше дә керә. Күкәй авыру хайваннар йонынннан, туфрак өслегеннән, үлән, җиләк һ.б.дан арадаш хуҗаның эчәклегенә эләгә һәм алардан личинка-онкосфералар барлыкка килә. Эчәклек стенкасы аша алар капка венасына керә һәм кан б-н бавырга, үпкәгә, мускулларга китә, биредә ларвоцистага әверелә (15 *см* га кадәрге һәм аннан да зуррак үлчәмдәге эхинокоз куык). Ана куык күпсанлы башлы өстәмә куыклардан тора. Бу стадиядә Э. куркыныч эхинококкоз авыруын китереп чыгара. Күп еллар дәвамында куыклар төрле билгеләр (авырту, зарарланган органның күләме зураю, анемия, сары авыруы, асцит һ.б.) б-н сиздереп арадаш хуҗада яшәргә мөмкин. Үпкәдә аларны локальләштергәндә авыру күренеше туберкулёзны хәтерләтә.

*О.Д.Любарская.*

**«Э́ХО ВЕКО́В»**, журнал; к. «*Гасырлар авазы – Эхо веков*».

**ЭЧӘККУЫШЛЫЛА́Р** (Coelenterata, Cnidaria), умырткасыз хайваннар төре. Протерозойның венд чорында барлыкка килгән борынгы күпкүзәнәкле организмнар. Башлыча, диңгездә, күбесе колонияләргә оешып яшәүгә җайлашканнар. 8–10 мең төре билгеле. Зурлыгы берничә мм дан 10–15 *м* га кадәр, мәс., сифонофоралар (Physalia), арктик медузалар (Cyanea capillata). 2 төрле тереклек формасы хас (берәр әйбергә ябышкан полип һәм ирекле йөзүче медуза), тереклек циклы дәвамында алар чиратлашып килергә мөмкиннәр (метагенез), яисә бер форма юкка чыга (гипогенез). Аерым затларның гәүдәсе ике күзәнәк катлавыннан (тукымадан): эпидермис (эктодерма) һәм гастродермистан (энтодерма) тора; алар арасында структурасыз койкасыман матдә (мезоглея) ята. Э. өчен гәүдәнең нурлы симметрияле һәм ук капсулалары барлыкка китерүче чаккыч күзәнәкләр булуы (нематоцисталар) хас. Авызы азыкны эләктереп алу өчен хезмәт итүче һәм төркем булып («батареяләр») чаккыч күзәнәкләр урнашкан кармавычлар б-н әйләндереп алынган. Ашкайнату куышлыгы капчыксыман яки камераларга бүленгән, эшкәртелмәгән калдыклар авыз аша чыгарыла. Нерв системасы диффузлы типта, гастродермиста урнашкан. Җенси һәм җенессез (бөреләнеп) юл б-н үрчи. Күпчелек Э. — ерткычлар, планктон һәм шактый зур су организмнары б-н туеналар. Күбесе башка организмнар (балыклар, ялгыз кысла, беркүзәнәкле суүсемнәр — зооксантеллар һ.б.) б-н төрле симбиоз формаларына керә. Мәрҗән полиплар классыннан мадрепор мәрҗәннәр сай сулы тропик диңгезләрдә калын корылмалар — уникаль риф экосистемалары тудырып рифлар (яр буе, барьер, атолл рифлары) барлыкка китерәләр. Күп кенә илләрдә кызыл яки затлы (Corallium rubrum), кара (Antipatharia) мәрҗәннәрдән ясалган бизәнү әйберләре югары бәяләнә. Кайбер Э.ның чаккыч күзәнәкләренең агуы кеше өчен куркыныч тудыра һәм «пешү» нык авырту, кайвакыт үлемгә китерергә мөмкин (субтропик һәм тропик суларда — сифонофоралар, кубомедузалар, ерак көнчыгыш диңгезләрендә — әвернәле медуза һ.б.). Э. су чисталыгының индикаторы булып торалар.

Э.ның өч классыннан Татарстан терр-ясендә гидрозалар классы (Hydrozoa) очрый, вәкилләреннән Hydrida отрядыннан *гидралар* ыругының 3 төре бар. Алар чиста сулы, су асты үсемлекләренә бай сулыкларның яр буе зоналарында яшиләр.

*Әд.:* Н а у м о в Д.В. Гидроиды и гидромедузы морских, солоноватоводных и пресноводных бассейнов СССР. Л., 1960; Ж а д и н В.И., Г е р д С.В. Реки, озёра и водохранилища СССР. М., 1961; Д о г е л ь В.А. Зоология беспозвоночных. М., 1981; Определитель пресноводных беспозвоночных России. СПб., 1994. Т. 1.

*Р.М.Сабиров.*

**ЭЧКЕ́ РОССИ́Я МӨСЕЛМАННАРЫ́ ЭШЛӘРЕ́ КОМИССАРИАТЫ́**, 1918 елның гыйнварында РСФСРның Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты составында төзелә. 1918 нең октябреннән әлеге исемдә. Мондый комис-т төзү идеясе 1917 нең ахырында туа: И.В.Сталин Ә.Цаликов б-н 1 декабрьдәге очрашуы вакытында Россия мөселманнары б-н хезмәттәшлекне барлык күпсанлы мөселман халыклары вәкилләрен үз эченә алган Комис-т төзү аша оештырырга тәкъдим итә. 1918 нең 7 гыйнварында бу мәсьәлә В.И.Ленин һәм И.В.Сталинның татар сәясәт эшлеклеләре Г.Г.*Ибраһимов*, М.М.*Вахитов* һәм Ш.Ә.*Манатов* б-н очрашуында тикшерелә, шуннан соң, 1918 нең 17 гыйнварында, В.И.Ленин һәм И.В.Сталин Комис-т төзү турында Декретка кул куялар. Беренче җитәкче итеп М.М.Вахитов, урынбасарлар итеп Ш.Ә.Манатов һәм Г.Г.Ибраһимов билгеләнәләр. Башкорт эшләре буенча аерым Комис-т оештырырга ниятләгән башкорт халкы вәкилләре йогынтысында, 1918 нең 29 мартында ул Үзәк татар-башкорт комис-ты дип үзгәртелә. Андый атама Россиянең башка мөселман халыкларын канәгатьләндерми, 1918 нең 14 апрелендә яңа исем — Үзәк мөселман комис-ты кабул ителә.

Мөселманнар күпчелек тәшкил иткән төбәкләрдә сәясәт һәм мәдәни-агарту эшләре, мөселман хәрби частьлары оештыру, нәшрият эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. Комис-тта (1918 нең апреле) хезмәт (комиссар Х.З.*Гайнуллин*), финанс (И.Әсәкаев), хәрби (Й.И.*Ибраһимов*), халыкара пропаганда (М.М.Вахитов), матбугат ( (Г.Килдебәков), игенчелек (Г.Г.Ибраһимов һәм Г.Аетбаев), башкорт (Т.Имаков) бүлекләре эшли. Алга таба Комис-т үзгәртеп корыла, аның элекке бүлекләре бетерелә һәм яңалары төзелә. 1918 нең ноябре ахырына аның составында 4 бүлек: гомуми, мәдәни-агарту (Г.Т.Гыйсмәти), нәшрият (Г.Г.Ибраһимов), стат. (Ульянинский) бүлекләре кала. Рәисе итеп М.*Солтангалиев* билгеләнә. Бер үк вакытта Комис-тның эшчәнлек даирәсен бөтен Россия буенча җәелдерү эше алып барыла. 1918 нең 27 гыйнварында Милләтләр эшләре буенча халык комис-тының «Депутатлар советлары каршында Эчке Россия мөселманнары эшләре буенча Комиссариат бүлекчәләрен оештыру турында» карары кабул ителә. Комис-т бүлекләре илнең 70 торак пунктында, ш.и. Казанда, Уфада, Төмәндә һ.б. шәһәрләрдә эшләп килә. Аларга мөселманнар арасында Совет хакимияте күрсәтмәләрен пропагандалау, Халык комис-тының барлык карарларын гамәлгә ашыру, милләтләрнең хезмәт ияләренең мәдәни дәрәҗәсен һәм сыйнфый үзаңын күтәрү буенча чаралар уздыру, контррев-ция б-н көрәш бурычлары йөкләнә. Комис-т Совет хакимиятенә каршы чыгучы мөселман оешмалары эшчәнлеген тыя: аның карары буенча «*Ил*» г-тасы ябыла, Мәскәүдәге *Милли Шура* (Г.Исхакый җитәкчелек итә) һәм аның б-н бәйләнештәге барлык оешмалар гамәлдән чыгарыла, мөлкәтләре Комис-тка тап-

шырыла. 1918 нең 21 апрелендә Комис-т карары буенча Эчке Россия һәм Себер мөселманнары мәдәни-милли автономиясенең Милли идарәсе (*Милли Идарә*) таратыла. Урыннарда автономия органнары ш.у. бетерелә. Комис-т Совет хакимиятен саклау өчен мөселман хәрби частьларын оештыруда катнаша. 1918 нең 26 февралендә аның мөселман соц. армиясенә язылырга чакырган «Революцион мөселман халкына» мөрәҗәгате басылып чыга. Махсус мөселман Кызыл Армиясе оештырыла. Комис-тның хәрби бүлегендә аның частьларын туплауның һәм эшчәнлегенең билгеле бер принциплары эшләнә. Мөселманнарны армиягә җәлеп итү максатында урыннарга Комис-т вәкилләре җибәрелә. Петроградта, Мәскәүдә һәм Әстерханда аның тырышлыгы б-н беренче хәрби частьлар формалаша. 1918 нең 2 маенда И.В.Сталин Кызыл Армия составында Мөселман эшче-крәстиян армиясен төзү турында Халык комис-ты карарына кул куя; аны оештыру Комис-тка йөкләнә. 1918 нең язында — көзендә ул ш.у. Татар-башкорт Автономияле Совет респ-касы оештыру буенча хәзерлек эше алып бара. Комис-т оештыру съездын чакыру б-н шөгыльләнергә тиеш була. В.И.Ленин күрсәтмәсе б-н аңа әлеге проектны гамәлгә ашыру өчен 90180 сум күләмендә акча бүлеп бирелә. Комис-тның эшчәнлеге Шәрекъ халыклары коммунистлар оешмаларының 1 нче һәм 2 нче Бөтенроссия съездларында тикшерелә. 1920 дә ул *Татарстан Республикасының РСФСРдагы вәкаләтле вәкиллеге* итеп үзгәртелә. Вакытлы басмасы — «*Чулпан*» г-тасы.

*Әд.:* Хайрутдинов Р.Г. На путях к Советской автономии. Проведение ленинской национальной политики Центральным татаро-башкирским комиссариатом в 1918 — 1919 гг. К.,1972; Тагиров И.Р. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000; Исхаков С.М. Российские мусульмане и революция (весна 1917 г. — лето 1918 г.). М., 2004.

**ЭЧКЕ́ РОССИ́Я һӘМ СЕБЕ́Р ТӨРКИ́-ТАТАРЛАРЫНЫ́Ң МИЛЛӘ́Т МӘҖЛЕСЕ́**, к. *Милләт Мәҗлесе*.

**ЭЧКЕ́ РОССИ́Я һӘМ СЕБЕ́Р ТӨРКИ́-ТАТАРЛАРЫНЫ́Ң МИЛЛИ́ ИДАРӘСЕ́**, к. *Милли Идарә*.

**ЭЧКЕ́ ТУЛА́Й ПРОДУ́КТ**, ил терр-ясендә базар бәяләрендә соңгы продуктның һәм күрсәтелгән хезмәтләрнең тулай бәясен билгеләүче статистиканың гомумиләштерелгән икътисади күрсәткече. Билгеле бер вакытта икътисад субъектларының җитештерүдәге эшчәнлегенең соңгы нәтиҗәсен күрсәтә. Өч ысул б-н: өстәмә кыйммәт, керем һәм чыгым буенча исәпләнә. Халыкара операцияләрдән кергән керем Э.т.п.ка кертелми. Э.т.п.ны исәпләгәндә БМОның Милли хисап системасы тәкъдимнәре кулланыла. Татарстан терр-ясендә Э.т.п. урынына эчке региональ продукт (ЭРП) исәпләнә, аңа федераль дәүләт җитештергән барлык продуктлар һәм күрсәтелгән хезмәт (оборона, дәүләт идарәсе), ш.у. импортка салым кертелми. 1999 елда ТРда ЭРП 101,3 млрд. сум тәшкил итә, 2016 да Э.т.п. 1,9 трлн. сумга җитә. Аның структурасында: сәнәгать — 44,1%, төзелеш — 8,6%, транспорт һәм элемтә — 7,7%, а.х. — 7,1% тәшкил итә.

*Әд.:* Статистический сборник Госкомстата РТ. К., 2016.

**«ЭШ»**, газета; к. «*Ватаным Татарстан*».

**«ЭШ ТАҢЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. Профсоюзларның Бөтенбашкортстан советы органы. 1921–22 елларда Эстәрлетамак шәһәрендә аена 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барысы 6 саны чыга; беренче саны 1921 нең сентябрендә дөнья күрә. Башкортстанда беренче профсоюз газетасы. Мөхәррире — Т.Кәримуллин. Төп игътибар респ-ка һәм илдәге профсоюзлар эшчәнлеген яктыртуга, профсоюзлар хәрәкәтен халык хуҗалыгының төрле тармакларында пропагандалауга юнәлтелә. Газета *яңа икътисади сәясәт* һәм профсоюзларның халык хуҗалыгын торгызудагы роле мәсьәләләрен аңлата, хезмәт ияләрен фәнни-техник белем дәрәҗәсен күтәрергә чакыра. Сәяси вакыйгалардан редакция Советларның 9 нчы Бөтенроссия съезды эшен аерым билгеләп үтә. Һөнәрчеләр, кооператорлар һ.б. берлекләр эшчәнлеге турында язмалар бастыра. Мәкаләләрнең бер өлеше мәгариф һәм мәдәният мәсьәләләренә багышлана. Акча булмау һәм җирле профсоюзлар хәрәкәте сүлпәнәю сәбәпле, чыгудан тукталды.

**«ЭШКӘ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Самара губерна ком-ты каршындагы татар-башкорт коммунистларының пропаганда бүлеге һәм Самара губерна азчылык милләтләр бүлеге каршындагы татар-башкорт бүлекчәсе органы. 1921–22 елларда Самара шәһәрендә татар телендә атнага 2 тапкыр нәшер ителә; беренче саны 1921 нең 4 февралендә чыга. Газетада ВКП(б) сәясәте аңлатыла, 11 нче партия съезды эше турындагы материаллар басыла. Идел буендагы ачлык һәм аның б-н көрәш темасына зур игътибар бирелә; чәчү эшенә әзерлек һәм крәстиян имана җире бүлеп бирү проблемалары яктыртыла. Милли мәсьәләләр арасында татар яшьләренең сәяси активлыгын күтәрү темасы аерылып тора. Самара губернасында яшәүче татар халкының мәдәни тормышы турындагы мәгълүматлар, аерым алганда, «Шәрекъ» труппасы куйган спектакльләргә күзәтүләр бирелеп барыла, Л.Җәләй, Г.Садри һ.б. татар шагыйрьләре һәм язучылары әсәрләре басыла. *З.З.Гыйләҗев.*

**ЭШСЕЗЛЕ́К**, икътисади актив халыкның билгеле бер өлешенең төрле сәбәпләр аркасында вакытлыча иҗтимагый файдалы хезмәттән чыгарылуында чагылыш тапкан социаль-икътисади күренеш. РФдә һәм ТРда эшсезләр исәбенә исәпкә алу чорында эшләре яки керемле башка шөгыльләре булмаган, эш эзләгән (мәшгульлек хезмәтләре ярдәмендә яки мөстәкыйль рәвештә) һәм эшкә керешергә әзер 16 яшьлек һәм өлкәнрәк затлар керә. Эш эзләүнең тәгаен төрләре булып эшкә урнаштыручы дәүләт учреждениеләрендә (хезмәт биржаларында) теркәлү, турыдан-туры пр-тиеләр администрациясенә яки эш бирүчеләргә (эшмәкәрләргә) мөрәҗәгать итү, газетада игълан урнаштыру һ.б., ш.у. затның үз эшен оештыру омтылышлары (лицензия, бина, машиналар, җиһазлар, фермер хуҗалыгы алып бару өчен җир алу һ.б.) санала. Эшсезләрнең (мәшгульлек хезмәте системасында теркәлгәннәрнең дә, теркәлмәгәннәрнең дә) гомуми саны йорт хуҗалыкларын социаль-демографик нисбәттә тикшерүләр материаллары буенча ачыкларга мөмкин. Э.нең төп күрсәткечләре — аның дәрәҗәсе (эшсезләрнең икътисади актив халык эчендәге өлеше) һәм дәвамлылыгы (эш эзләү башланган мизгелдән эшкә урнашу мизгеленә кадәрге яки каралган чордагы вакыт аралыгы).

Э.нең төрле төрләре бар. Фрикцион Э. — эш эзләү яки аның булуын көтү б-н бәйле шөгыльсезлек — хезмәткәрләрнең бер эштән икенчесенә күчүе (иректе хәлдә яки эштән җибәрелү аркасында) нәтиҗәсендә хасил була. Структур Э., кагыйдә буларак, эшсезләрнең, һөнәри яки геогр. яктан, булган эш урыннары б-н туры килмәве сәбәпле, эшче көч структурасының эш урыннарының яңа структурасы б-н ярашмавына бәйле. Циклик Э. яки ихтыяҗ кытлыгы б-н бәйле Э., җитештерүнең кимүе — тулай чыгымнар җитмәү хас булган икътисади үсеш цикллары фазасы аркасында килеп чыга. Технол. Э. автоматлаштыруга һәм яңа технологияләр гамәлгә кертелүгә бәйле рәвештә эшче көчнең җитештерүдән кысрыклап чыгарылуы нәтиҗәсеннән гыйбарәт. Сезонлы Э. билгеле бер чорларда гына (мәс., а.х. культураларын җыеп алганда сезонлы эшләрнең кызу чагында) эш б-н тәэмин ителгән затлардан хасил була.

Татарстан терр-ясендә, Россиядәге кебек үк, Э. капиталистик мөнәсәбәтләр формалашкан чорда һәм иректе-яллы хезмәт асылы оешу процессында барлыкка килә. 1860 еллар башына Казан губернасында 100 меңнән артык иректе ялланган хезмәтче, ш.и. 4 меңләп эшче исәпләнә. Казанда көнлекле һәм сезонлы эшләргә ялланырга әзер 12 меңнән артык хезмәтче һәм крәстиян була. Әмма рәсми булмаган Э. (өлешчә яки ярым-йорты шөгыльсезлек) элегрәк тә яшәп килә. Мәс., 16–18 йөзләрдә аз җирлелек һәм җирле кәсепләрнең үсеш алмавы аркасында авыллар-да, ш.у. шәһәр халкы (һөнәрчеләр, эш кешеләре һ.б.) арасында шөгыльсезләр шактый була. *Казна эшенә беркетелгән крәстияннәрнең* (1807), *посессион крәстияннәрнең* (1849) һәм халыкның башка катлауларының крепостной бәйлелектән чыгарылуы нәтиҗәсендә эшсезләр саны күпкә арта. Реформалар чорында капиталистик мөнәсәбәтләр үсешенең тизләнүе Э.нең ачык формасы хасил булуга китерә. Крепостной хокук бетерелгәннән соң (1861) эшсезләр сафлары крәстияннәр хисабына арта башлый. Мәс., 1905 тә Казан губернасыннан 200 меңләп кеше читкә китеп эшлиләр. Шул ук вакытта губернага Россиянең башка төбәкләреннән эшсезләр агылуы күзәтелә (1897 дәге халык исәбе мәгълүматлары буенча аларның саны 64 мең кешедән арта, ягъни барлык халыкның 3% ын тәшкил итә). Төбәктә циклик Э.нең төп сәбәбе 19 йөзнең 70–80 елларындагы кризислар һәм 20 йөз башындагы депрессия була. Казан гу-

бернасында эшсезләрне беренче тапкыр рәсми теркәү Окт. рев-циясеннән соң уздырыла. 1917 нең декабрендә Казанда 9,5 меңгә якын эшсез кеше исәпләнә. Аларны теркәү, пособиеләр бирү, исәпкә алу һәм халык хуҗалыгында эш урыннарына билгеләү өчен РСФСР ХКСның 1918 ел 31 май декреты нигезендә Казанда хезмәт биржасы оештырыла. 13 меңнән артык эшсезләр теркәлә. Гражданнар сугышы, ул китергән җимерекләр һәм ачлык Э.не арттыралар. Шәһәрләрдә эшсезләр саны 50 мең кешегә җитә. 1926–29 да 30 меңнән артык эшсезләр төзелеш һәм сәнәгать пр-тиеләренә, төрле белгечләр әзерләү курсларына җибәрелә. 1930 ның октябренә респ-када рәсми теркәлгән эшсезләр саны 1360 кеше исәпләнә. А.П.Алексеевский исәпләве буенча авылларда ихтимал эшсезләр саны 200 мең кешедән арта. 1930 елларда хезмәт биржасы ябылу (1931) б-н бәйле рәвештә эшсезләрне теркәү туктатыла һәм СССРда Э.нең тулысынча бетерелүе игълан ителә. Чынлыкта аңа тулаем чик куелмый, ул ябык рәвештә (тулысынча мәшгуль булмау, сезонлылык һ.б.), бигрәк тә авыл җирендә саклана. 1960–80 елларда Татарстанда җитештерүгә фәнни-техник рев-ция казанышларын кертү чорында технол. һәм структур Э. хасил була. 1980 еллар ахырында — 90 еллар башында икътисадтагы структур үзгәрешләр һәм җитештерүнең азаюы аркасында эшче көчкә ихтыяҗ кимү нәтиҗәсендә ачык Э. шактый арта. Әлеге факторлар тәэсирендә мәшгуль халык халык хуҗалыгы тармаклары арасында яңадан бүленә. 1990 еллар башында оборона сәнәгате һәм җиңел сәнәгать пр-тиеләрендә мәшгульлек аеруча сизелерлек дәрәҗәдә кими. Хезмәт күрсәтү өлкәсендә, бигрәк тә базар инфраструктурасы б-н бәйле арадашчылык, финанс эшчәнлеге тармакларында, ш.у. нефть чыгару сәнәгатендә эшләүчеләр саны тотрыклы рәвештә арта. Гомуми алганда, ТРда хезмәт базары кадрларның хәрәкәтчәнлеге б-н сыйфатлана. Хезмәткәрләрнең хезмәттән китүенең төп сәбәбе — аларның үз теләкләре белән эштән чыгуы. Штатлар кыскару сәбәпле хезмәттән китү очраклары аз була (азат ителүче хезмәткәрләргә законнар нигезендә ярдәм итү өчен матди мөмкинлекләр булмавы аркасында пр-тиеләр эштән җибәрүнең андый формасын кулланмыйлар). Шул ук вакытта күп кенә пр-тиеләрдә администрация инициативасы б-н түләүсез яки өлешчә түләүле мәҗбүри ялга җибәрү гамәлгә кертелә. Хезмәт хакының үз вакытында түләнмәве чынлыкта Э.нең бер формасы булып тора. Ябык (рәсми булмаган) Э., ягъни сәнәгать һәм а.х. пр-тиеләрендә кулланыла торган җитештерү технологиясе һәм техник кораллану кысаларында эшләрнең фактик күләмен башкару өчен зарур булганнан күбрәк эшче көч тоту, теркәлүче Э.кә караганда шактый киңрәк колач ала. Шуңа күрә 1990 еллар башында эшсезләрне теркәү кабат гамәлгә кертелә. 1999 да ТРның мәшгульлек хезмәтләрендә 24,4 мең эшсез кеше теркәлә. Соңгы елларда аларның саны кими, 2017 ел ахырына ТРда рәсми рәвештә теркәлгән эшсезләр саны 11,8 мең кеше тәшкил итә.

Ахыр чиктә Э. кеше ресурсларын нәтиҗәсез файдалануны һәм аның б-н бәйле рәвештә югары дәрәҗәле тулай милли табыш күләменең килүен чагылдырып кына калмый, халыкны зур социаль чыгымнарга дучар итә һәм җәмгыятьтә тирән эз калдыра — гаиләләрдә психол. уңайсызлыкларга, халыкта авыруларның һәм үлем-китемнең артуына китерә.

ТРда Э.кә каршы көрәш өчен төрле алымнар — җитештерүне киңәйтү һәм эшчәнлекнең яңа өлкәләрендә эш урыннары булдыру, ташламалы кредитлау яки сәнәгать пр-тиеләренә салым ташламалары бирү, пр-тиеләрнең тулы булмаган эш атнасына күчүе, керем алу күздә тотылмаган вакытлыча эш урыннары булдыру (җәмәгать эшләре), эшчеләрне яңадан әзерләү һәм аларның һөнәри квалификациясен күтәрү кулланыла. 1990 еллардан респ-када Э. буенча пособие түләнә. Ш.у.к. *Хезмәт биржасы.*

*Әд.:* Алексеевский А.П. Население Татреспублики и запасы труда // Труд и хозяйство. 1927. № 3–4; Белялов У.Б. Руководство Коммунистической партии социалистической индустриализацией в национальных республиках Среднего Поволжья (1926–1940). К., 1978; Рабочий класс Татарии (1861–1980). К., 1981; История Казани: В 2 т. К., 1988–91; Народонаселение: Энцикл. словарь. М., 1994; Низамов И.А. Научно-технический прогресс и кадры. Елабуга, 1998; Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2001.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ЭШЧЕ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ушма елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 11 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Мамадыш кантоны Мамадыш волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1926 да — 119, 1949 да — 116, 1958 дә — 131, 1970 тә — 137, 1979 да — 93, 1989 да — 33, 2002 дә — 13 кеше.

**«ЭШЧЕ́»**, эшчеләрнең үзәк газетасы. РКП(б)ның Үзәк һәм Казан ком-тлары, 1918 елның августыннан — РКП(б)ның Мөселман оешмалары Үзәк бюросы, 1919 ның августыннан — РКП(б) ҮК каршындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмалары Үзәк бюросы, 1921 нең апреленнән — РКП(б) каршындагы Төрки халыклар арасында агитация һәм пропаганда Үзәк бюросы һәм Милләтләр эшләре халык комис-ты, 1923 нең октябреннән — РКП(б) каршындагы Татар-башкорт секциясе Үзәк бюросы, 1928 нең гыйнварыннан — ВКП(б) ҮК каршындагы Татар-башкорт бюросы, 1930 дан — СССР ҮБКның Милләтләр Советы органы. 1918 нең 27 сентябреннән Казанда, 1918 нең 13 декабреннән Мәскәүдә, 1920 нең 2 февраленнән кабат Казанда, 1921 нең 10 апреленнән 1931 нең 31 декабренә кадәр яңадан Мәскәүдә нәшер ителә. Көндәлек газета, татар телендә басыла, барысы 2039 саны чыга. Мөхәррирләре — И.Рәхмәтуллин, Б.Мансуров, В.Шәфигуллин, С.Атнагулов, Х.Гайнуллин, С.Сәгыев, М.Давыдов, Н.Сәйфи, З.Йосыпов (Шәркый), Х.Ишбулатов, И.Агишев. Газетада К.Абрамов, Ш.Әхмәдиев, М.Җәлил, М.Дулат-Али, Ә.Ерикәй, Г.Ибраһимов, Ш.Ибраһимов, Ш.Измайлов, М.Конов, С.Сәетгалиев, М.Солтангалиев, Х.Урманов, К.Якупов язмалары һәм әсәрләре басыла. Газета битләрендә даими рәвештә ВКП(б)ның Милләтләр оешмалары һәм Партия ҮКның Татар-башкорт бюросы эшчәнлеге яктыртыла. Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының 1 нче һәм 2 нче съезды (Мәскәү; 1918, 1919) эшләре, партиядә «тайпылышлар», бигрәк тә «солтангалиевчелек» б-н көрәш, илнең иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышы, Гражданнар сугышы барышы, 1921–22 еллардагы ачлык б-н көрәш, яңа икътисади сәясәтне гамәлгә ашыру, татар эшчеләре һәм крәстияннәренең индустрияләштерүдә, күмәкләштерүдә һәм культура рев-циясендә катнашуы, яңа икътисади сәясәтне гамәлгә ашыру турында җентекле мәгълүмат бирелә. 1931 дә редакция «Подольск эшчесе» (Мәскәү өлкәсенең Подольск ш., мөхәррире В.Садри) кучмә г-тасын, 1929–30 да кушымта итеп, татар теленнән латин графикасына күчү мәсьәләләренә багышлап «Белем ачкычы» г-тасын (17 сан) чыгара. 1932 дә «Эшче» һәм «*Игенчеләр*» г-талары җирлегендә «*Коммунист*» г-тасы чыга башлый.

*Т.М.Насыйров.*



«Эшче» газетасы.

**«ЭШЧЕ́»**, к. *Татар сәнгать эшче театры.*

**«ЭШЧЕ́»**, 5 күренештән торган опера. Авторлары — Г.Әлмөхәммәдов, В.Виноградов һәм С.Габәши. М.Гафуриның шул исемдәге үз поэмасына нигезләнеп язган либреттосы. Премьерасы 1930 елның 28 февралендә һәм 9 мартында Татар акад. театрында була, шул ук елны опера Мәскәүдә СССР милли театрлар олимпиадасында күрсәтелә. Дирижёры — А.Литвинов, режиссёры — С.Вәлиев-Сульва, рәссамы — П.Сперанский, балетмейстеры — Ю.Муко, хормейстеры — С.Габәши. Төп партияләрне Г.Әлмөхәммәдов, Н.Рәхмәтуллина, С.Айдаров, К.Хисамов һ.б. башкара. Спектакльдә Шәрекъ музыка техникумы оркестры һәм хоры катнаша. «Э.» — тарихи-революцион темага язылган тәүге совет операларының берсе (1905 елгы рев-ция чорындагы вакыйгалар бәян ителә). 1931 дә кабат Татар драма театрында куела: режиссёры — Х.Сәлимҗанов, балетмейстеры — Г.Та-





«Эшче» операсыннан күренешләр. 1930.

һиров, дирижёры — С.Сәйдәшев. «Э.»дә, нигездә, татар фольклоры традицияләре гамәлгә ашырыла; төп арияләр, хорлар һ.б. номерлар б-н бергә «Казан сөлгесе», «Тамчы тама», «Тәфтиләү» кебек халык җырлары да яңгырый.

Кайбер арияләр һәм хор әсәрләре башкорт җыр һәм бию көйләренә якын тора. Батырлык-рев-ция темасы опера партитураларына рев-ция һәм совет тематикаларына күмәк башкарыла торган җыр һәм марш музыкасы интонацияләрен һәм ритмнарын кертү өчен сәбәп була.

«Э.» (шул ук авторларның беренче татар «Сания» операсы кебек үк) милли музыка традицияләре б-н Европа муз. классикасы чаралары синтезына нигезләнә. Операдагы кайбер номерлар, мәс., Нигъмәт ариясе татар җырчылары репертуарына керә.

*Ф.Ш.Салитова.*

**«ЭШЧЕ́ ТАВЫШЫ́»**, газета. Украина КП(б) ҮК каршындагы Татар-башкорт секцияләре Үзәк бюросы органы. 1920 елда Харьков шәһәрендә татар телендә нәшер ителә.

**«ЭШЧЕ́ ХАЛЫ́К СҮЗЕ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. Семипалатинск губерна революцион ком-ты каршындагы төрки халыклар секциясе һәм РКП(б)ның губерна бюросы органы. 1919–20 елларда Семипалатинск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, беренче саны 1919 ның декабрендә басыла.

*Әд.:* И б р а г и м о в Г. Сочинения. Т. 5. Труды и статьи о литературе и искусстве (1910–1933). К., 1978.

**ЭШЧЕ́ ЯШЬЛӘ́Р БЕРЛЕГЕ́**, Татарстанда беренче коммунистик яшьләр оешмасы. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң, революцион партияләрнең сәяси тормышы һәм агитациясе активлашу б-н, Казанда яшьләр хәрәкәте көчәя. 1917 нең язында зур сәнәгать пр-тиеләре урнашкан Елга аръягында эшче яшьләр түгәрәге барлыкка килә. А.Табейкин, П.Ильин, С.Шмаков, Т.Романова, З.Путилов аның актив әгъзалары була. Алар сәяси әдәбиятны өйрәнәләр, М.Горький, Д.Бедный әсәрләрен укыйлар, сәяси мәсьәләләр буенча дискуссияләр алып баралар; П.Ильин һәм А.Табейкин РСДРП(б)ның Казан ком-ты әгъзалыгына кабул ителәләр. 1917 нең 4 июлендә Ягодный бистәсендәге Алафузов эшчеләр театрында Казанның революцион яшьләре җыелышы булып уза, аңа Дары һәм Алафузов з-длары эшчеләре, солдатлар, укучылар килә (барлыгы 150 дән артык кеше). Җыелышның рәисе А.Табейкин, секретаре П.Ильин була. А.Табейкин доклад ясап, булачак Берлекнең максатларын, аның программасын бәян итә һәм яшьләрне берләшергә чакыра; П.Ильин, пролетар оешма булырак, Берлек бөтен ил яшьләренең берләшүенә омтылырга һәм Яшьләр Интернационалының секциясенә әверелергә тиешлеге турындагы фикерен белдерә, Берлекнең төп бурычы сыйнфый үзаңны үстерү һәм аның әгъзаларының мәдәни-әхлакый дәрәҗәсен күтәрү булырга тиешлеген әйтә. Җыелыш оешма төзү турындагы тәкъдимне хуплый һәм вакытлы оештыру ком-ты сайлап куя, аның составына Н.Аверьянова, П.Ильин, А.Табейкин һ.б. керә. Аның сәяси платформа буенча утырышында Берлекнең «Интернационал байрагы астында» эшләячәге, үз карарларын «Казанская рабочая газета», «Рабочий», «Социалист-революционер» г-таларында бастырачагы хәл кылына. Берлек ком-ты рәисе булып А.Табейкин (яшеренлек өчен С.Калининның рәис булуы хәбәр ителә), секретарь итеп П.Ильин сайлана. Оештыру ком-ты ш.у. Берлекнең уставын эшләү өчен комиссия төзи. Оешма әгъзалары революцион газеталар һәм листовкалар тараталар, социаль-демократик матбугат б-н хезмәттәшлек итәләр, аңа булышу өчен акча җыялар, эшчеләр оешмалары эшчәнлегендә актив катнашалар («Дары з-дында» завод ком-тына — И.Шулаков, Алафузов з-дыныкына С.Шмаков һ.б. керә). 1917 нең августында устав проекты әзер була, ул Н.К.Крупскаяның «Эшче яшьләр берлегенең үрнәк уставы» («Примерный устав Союза рабочей молодежи», «Правда», 1917, 7 июнь) мәкаләсенә нигезләнә. 1917 нең 11 августында дары з-ды завод ком-ты бинасында оешманың 2 нче җыелышы уза (рәисе К.Васкевич була), анда Берлекнең уставы кабул ителә, әгъзаларның 15–22 яшьтә булырга тиешлеге, Берлеккә керү өчен тәкъдимнамәләр таләп ителмәве күрсәтелә. Берлек идарәсенә К.Васкевич, П.Ильин, Каммер, А.Табейкин, П.Тупоногов сайлана; оешма Социалистик яшьләр берлеге дип үзгәртелә. Берлек ком-ты «III Интернационал» Эшче яшьләр берлеге (Мәскәү) б-н элемтә урнаштыра, 2 башлангыч оешма (Дары һәм Алафузов з-дларында), 4 түгәрәк (агымдагы сәясәт, политэкономия, әдәбият һәм муз. драма буенча) төзелә. Оешма РСДРП(б)ның Казан ком-ты җитәкчелегендә эшли. Активистлар большевикларның Казан шәһәр думасына сайлау кампаниясендә катнашалар. 1917 нең 13 сентябрендә дары з-дында узган 3 нче җыелышта большевиклар тарафыннан кораллы күтәрелешкә юнәлеш алынганнан соң, Берлек яшьләрнең сугышчан дружинасын төзү турында карар кабул итә, хәрби һәм санитар эшкә өйрәнү оештырыла; полклар б-н элемтә өчен һәм дары з-ды ревкомы составына кешеләр билгеләнә. Кешеләрнең бер өлеше Кызыл Гвардия отрядларына керә, И.Понеделко Дары з-ды отряды командиры була. 1917 нең 21 сентябрендә Берлек ком-ты Казанның барлык районнары яшьләренә мөрәҗәгать итеп, сафларны берләштерергә һәм үзләренең өлкән «эшче иптәшләрен капитал изүеннән азат итү өчен көрәштә булышлык итәргә» чакыра. Берлек әгъзалары *Казанда 1917 елгы Октябрь кораллы баш күтәрелешендә* актив катнашалар. Табейкин һәм Шулаков Кызыл Гвардиянең Казан штабында эшче яшьләр вәкилләре булып торалар. Рев-циядән соң оешма ячейкалары Казанның күпчелек зур пр-тиеләрендә барлыкка килә, 1918 нең язына Берлектә 300 дән артык кеше исәпләнә. 1918 нең 21 апрелендә *Эшче яшьләр берлегенең беренче гомумшәһәр конференциясе* чакырыла. Төп бурычлар итеп сафларны берләштерү һәм совет хакимиятен яклау танылa. Конференция барлык эшне пр-тиеләрдә төзелгән ячейкалар аша оештыру һәм Берлекне «III Интернационал» Казан яшьләр берлегенә үзгәртү турында карар кабул итә. Казан Кызыл Армия гаскәрләре тарафыннан азат ителгәннән соң (1918, 10 сентябрь), акрынлап Берлек ячейкалары яңара бара, аның үзәген Елга аръягы һәм Постаучылар бистәсе эшчеләре тәшкил итә. Алар *Эшче яшьләр берлегенең беренче гомумшәһәр конференциясен* (Казан, 1919, 21 апрель) чакыруның инициаторлары була, анда шәһәрнең комсомол оешмасы төзелә. Ш.у. к. *Бөтенсоюз Ленинчыл коммунистик яшьләр союзы (ВЛКСМ).*

Чыг.: Татария в борьбе за победу пролетарской революции (февр.-окт.1917): Сб. док. и материалов. К., 1957.

*Әд.:* Страницы славного прошлого комсомола Татарии. К., 1958; Юность Татарстана (Очерки истории комсомола Татарии). К., 1978.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ЭШЧЕ́ ЯШЬЛӘ́Р БЕРЛЕГЕНЕ́Ң БЕРЕНЧЕ́ ГОМУМШӘҺӘ́Р КОНФЕРЕ́НЦИЯСЕ**, 1918 елның 21 апрелендә Казанда уздырыла. 300 делегат катнаша. РКП(б)ның Казан ком-ты тәкъдиме б-н чакырыла. Конференциядә А.Табейкин (секретарь), С.Алфимов, А.Михеев, К.Машкин, А.Соломин, Г.Тихомирнов, И.Шулоков составында Бер-

лек ком-ты сайлана, Берлекнең эшен фабрика һәм заводларда төзелгән ячейкалар аша оештыру турында карар кабул ителә. Конференциядә катнашучылар оешманы «III Интернационал» Казан яшьләр берлеге дип атарга хәл кылалар.

*Әд.:* Юность Татарстана (Очерки истории комсомола Татарии). К., 1978.

**ЭШЧЕ́ ЯШЬЛӘ́Р БЕРЛЕГЕНЕ́Ң БЕРЕНЧЕ́ ШӘҺӘ́Р КОНФЕРЕ́НЦИЯСЕ**, 1919 елның 21 апрелендә Казанда уздырыла. 100 гә якын делегат катнаша. Казан дары з-ды, элеккеге Алафузов пр-тиеләренең комсомол ячейкалары башлангычында чакырыла. РКП(б)ның губерна ком-ты конференцияне әзерләү буенча оештыру бюросы төзи. 12 апрельдә «Знамя революции» г-тасында «Яшьләргә мөрәҗәгать» басыла; анда конференция чакыру зарурлыгы, аның төп бурычы Россия коммунистик яшьләр берлеге (РКСМ) программасы һәм уставына ярашлы рәвештә, Казанда эшчеләр һәм укучы коммунистик яшьләр бердәм берлеге төзү икәнлеге турында бәян ителә. Конференциядә РКП(б)ның Казан губкомы вәкиле А.И.Карповның комсомол оешмасы турындагы докладлы тыңлана. РКСМның Казан оешмасын төзү турында карар кабул ителә, П.Ильин (рәис), Ю.Федимидин (секретарь), В.Бабиков, Х.Гарбер, А.Елисеев һ.б. составында РКСМның Казан шәһәр ком-ты сайлана. Конференциядә катнашучылар коммунистик яшьләрне «тыгыз сафларга басарга һәм үлеп баручы контрреволюциягә хәлиткеч сугыш ачарга» чакырган резолюция кабул итәләр.

*Әд.:* Юность Татарстана (Очерки истории комсомола Татарии). К., 1978.

**«ЭШЧЕЛӘ́Р ДӨНЬЯСЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Оренбург губерна ком-ты мөселман секциясе һәм Оренбург губерна башкарма ком-ты каршындагы мөселман эшләре бүлеге органы. 1919 елда Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә; беренче саны 1919 ның 30 гыйнварында дөнья күрә.

**ЭШЧЕЛӘ́Р СЫЙНЫФЫ́** (пролетариат), ялланып, башлыча, физик хезмәт башкаручы кешеләрдән торган социаль катлау. Казан төбәгендә Э.с. феодализм чорында ярала башлый. 17 йөздә гомумроссия базары формалашу б-н бергә һөнәрләрчеләр товар җитештерү базарында хезмәт бүленеше көчәя, феодаль бәйле һәм ялланып эшләүчеләр хезмәтеннән файдаланган пр-тиеләр барлыкка килә. Ләкин 17 йөзнең 2 нче яртысында — 18 йөздә эш кешеләре, сәнәгатьтәге Э.с.н гәүдәләндермичә, башлыча крепостной (алпавытлар милкендәге) крәстияннәр һәм дәүләт крәстияннәре була, дәүләт һәм хосусый хуҗалар аларны посессион һәм казна эшенә беркетелгән крәстияннәр (к. *Посессион крәстияннәр, Казна эшенә беркетелгән крәстияннәр*) сыйфатында заводларда һәм мануфактураларда (к. *Казан постау мануфактурасы*) эшләргә мәҗбүр итәләр. 18 йөз башына Казан төбәгендә эш кешеләренең исәбе 1,6 мең кешегә җитә. 1812 елда Казан губернасының сәнәгать пр-тиеләрендә 4,8 мең чамасы кеше, аларның күп өлеше постау (2,3 мең кеше), күн (811) һәм бакыр эретү (760 кеше) сәнәгате пр-тиеләрендә эшли. Эш кешеләренең хезмәт һәм тормыш шартлары бик авыр була, шул сәбәпле еш кына эш бирүчеләргә каршы күтәрелешләр кабатлана. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында *Казан постаучылары чуалышлары* Казан губернасында иң зур күтәрелешләр була. 1830–80 елларда, илдә капиталистик мөнәсәбәтләр урнашу (к. *Капитализм*), сәнәгый борылыш төгәлләнү һәм мануфактураларның фабрика-завод җитештерүе тарафыннан тәмам кысрыклап чыгарылуы чорында индустриаль Э.с. формалаша. Реформалар чорында эшчеләр саны якынча 2 тапкыр арта. 20 йөз башында 230 пр-тиедә 14 мең чамасы эшче һәм хезмәткәр, ш.и. җиңел сәнәгатьтә — 5,6 мең (өйдә эшләүчеләр б-н бергә), азык-төлек сәнәгатендә — 2,4 меңнән артык, металл эшкәртүдә — 1,5 мең, агач эшкәртүдә 1,1 мең кеше эшли. Эре машина җитештерү үсеше эшчеләрнең а.х.ннан аерылуына һәм сәнәгать пр-тиеләрендә даими эшче көч контингентының артуына (30%ка кадәр) китерә. Крестовниковлар з-дында даими эшчеләрнең чагыштырмача өлеше 1862–63 тә — 38,9%, 1889–90 да 71,5% тәшкил итә. Фабрика-завод җитештерүе б-н бер үк вакытта вак (кустарь) сәнәгать тә үсеш кичерә, анда 13,4 мең кеше исәпләнә, аларның зур өлеше крәстияннәр даирәсеннән чыккан, сезонлы эшчеләрдән гыйбарәт була. Эшчеләрнең чыгышлары б-н крәстияннәрдән булуы һәм аларның авыл б-н тыгыз элемтәләре саклануы реформалар чорында Э.с. ның крәстияннәргә хас психоменталь һәм әхлакый нормаларның көчле йогынтысын кичерүенә китерә (күмәклекнең җәмәгать рухы, белем дәрәҗәсенең чикләнгәнлеге, гадел патшага ышаныч, башлыкларны һәм руханиларны зурлау).

Э.с. формалашуның үзенчәлеге заводларның һәм фабрикаларның техник яктан түбән дәрәҗәдә җиһазландырылуы һәм эшче көчне экстенсив формаларда файдалану нәтиҗәсендә эшчеләрнең аеруча эре пр-тиеләрдә туплануыннан гыйбарәт була. 1913 тә эшчеләрнең 76% тан күбрәк өлеше губернаның эре пр-тиеләрендә (100 дән артык эшче; мәгълүматлар буенча, 212 пр-тие) эшли. Туплану процессында бер пр-тиедәге уртача эшчеләр саны 1879 да 51 кешедән 1913 тә 127 кешегә кадәр арта. Э.с.ның аеруча зур өлеше 25 завод һәм фабрикада, ш.и. *Алафузовлар завод-фабрикаларының сәүдә-сәнәгать ширкәте* җитен эрләү-туку пр-тиесендә (3 меңләп кеше) һәм Крестовниковларның *Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү һәм химия заводында* (2,3 мең кеше) туплана. Икенче үзенчәлек — Э.с.ның Казанда тыгыз тупланышы, 1913 тә анда барлык сәнәгать пр-тиеләренең 52,8% ы, шул ук вакытта губернаның өяз шәһәрләрендә (Чистайда, Спаста, Мамадышта, Тәтештә һ.б. да) бик аз сандагы эшчеләре б-н нибары 12,2% ы урнашкан. Э.с. формалашуның өченче үзенчәлеге аның составында күп санда ярымпролетарий-крәстияннәр булудан гыйбарәт. Мәс., 1913 тә губернадагы барлык пр-тиеләрнең 35% ы авыл торак пунктларында урнашып, яллы эшчеләрнең зур өлешен җирле крәстияннәр тәшкил итә. 19–20 йөзләр чигендә Казанның Э.с. милли структурасының төп өлешен руслар (77,8%) һәм татарлар (22%) хасил итә. Татар эшчеләре, башлыча, сәнәгатьнең үсемлек һәм хайван җепселләрен эшкәртү (20%) кебек тармакларында мәшгуль булалар. Рус эшчеләре җирле сәнәгатьнең барлык тармакларында диярлек, бигрәк тә металл эшкәртү (95,7%), азык-төлек җитештерү (86,3%) һәм агач эшкәртүдә (79,8%) әйдәүче урынны билиләр. Казан губернасында татар Э.с. формалашуның төп үзенчәлеге әлеге процессның җирле сәнәгатьтә төп урынны тоткан рус буржуазиясе җитәкчелегендә баруыннан гыйбарәт. 1913 тә 187 пр-тиене (91,5%) — рус буржуазиясе, 15 пр-тиене (4,3%) татар буржуазиясе вәкилләре били. Рус, өлешчә татар буржуазиясе милкендәге пр-тиеләрдә татар эшчеләре рус эшчеләренә караганда авыррак хәлдә булалар, чөнки аларның күпчелеге башлыча ярдәмче һәм аз түләүле эшләрдә файдаланыла. Алар арасында сезонлы эшчеләр — татар авылларыннан чыгучылар күп була. Татар Э.с.ның төп өлеше татар сәүдә-сәнәгать буржуазиясе вәкилләре *Акчуриннар, Рәмиевләр, Сәйдәшевләр*, Субаевлар, *Үтәмешевләр* һ.б. пр-тиеләрендә формалаша. Татар эшчеләренең аерым һөнәри отрядлары Көнчыгыш Себердәге һәм Урал алдындагы алтын приискларында, Урал металлургия з-дларында, Баку нефть промыселларында, Донбасстагы күмер шахталарында һ.б.да оеша. 1917 дә Донбасс пр-тиеләрендә — 35 мең тирәсе, Баку нефть чыгару сәнәгатендә — 5,3 меңнән артык, Орехово-Зуево пр-тиеләрендә 5 мең чамасы татар эшчеләре эшли. Бу чорда Россиядә 150 мең, ш.и. Казан губернасында 8–10 мең татар эшчесе исәпләнә. Аз җирлелек, еш кына иген уңмау, салымнарның артуы татар крәстияннәрен сәнәгый төбәкләргә китеп эшләргә мәҗбүр итә; Э.с.ның җирле һөнәри отрядларына кушылып, акрынлап элеккеге авыл көнкүрешеннән аерылып, аларның күбесе шунда озакка кала.

Икътисадта барган процесслар Э.с. тереклек эшчәнлегенең күп кенә яклары б-н үзара катлаулы һәм каршылыклы тәэсир итешә. 19–20 йөзләр чигендә сәнәгатьнең тиз күтәрелеше Россия җәмгыятендәге, эшчеләрнең тормыш шартларындагы һәм аларның аңындагы мөһим үзгәрешләр б-н туры килә. Тормыш темпларының һәм сыйфатының кискен үзгәрүе, мәнфәгатьләр бәрелеше җәмгыятьтә социаль киеренкелеккә, Э.с.ның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге активлашуга китерә. Эшчеләр икътисади һәм сәяси көрәшкә (пр-тиеләрдә стачкалар һәм забастовкалар) активрак тартыла, үзләренең һөнәри һәм иҗтимагый-сәяси оешмаларын (к. *Сәяси партияләр, Профсоюзлар*) булдыра башлыйлар. 20 йөз башындагы революцион вакыйгалар (к. *Россиядә 1905–07 еллар революциясе*) киң эшчеләр массаларының иске мораль нормаларыннан — күндәмлек, басынкылык сыйфатларыннан һ.б.дан читләшүенә, чынбарлыктагы хәл б-н килешмәүчәнлек, стачкачылар көрәшендә күмәкчелек, катгыйлык һәм ныклык кебек сыйфатлар булуга булышлык

итә. 1905–17 дә Казан губернасында 120 ләп стачка һәм забастовка булып уза, тулы булмаган мәгълүматлар буенча аларда 50 меңнән артык кеше катнаша. Нәтиҗәдә эш көне озынлыгын (уртача 13–14 сәгатьтән 10–11,5 сәгатькәчә кыскара), эш бирүчеләр таләп иткән штрафларны түләтү тәртибен билгеләгән закон актлары кабул ителә. 1900–13 тә эшчеләрнең уртача еллык хезмәт хакы 57,2% ка (127 сум 80 тиеннән 200 сум 92 тиенгә кадәр) арта. 1913 тә номиналь хезмәт хакы күләме буенча Казан губернасы Россиянең Европа өлешендәге 68 губернасы арасында 38 нче урынны били. 1912 нең 23 июнендә сәнәгать эшчеләрен авырулардан һәм бәхетсезлек очракларыннан иминиятләштерү турында законнар чыгарыла, шул рәвешчә *хастаханә кассалары* оештыру мөмкинлеге барлыкка килә. *Беренче бөтендөнья сугышы* елларында Казан губернасының Э.с. структурасында мөһим алга китеш була. Сугыш аркасында мобилизацияләр һәм җитештерүнең киңәюе Э.с.ның сан һәм сыйфат составына йогынты ясый. Әлеге чорда Э.с.ның саны шактый арта, 1917 гә ул 43,5 мең кешегә җитә (ш.и. 3,6 меңнән артык татар эшчеләре). Фронтның хәрби ихтыяҗларын тәэмин иткән химия, күн җитештерү һәм тегүчелек сәнәгатендә 30 меңгә якын кеше, шулардан Алафузов ф-каларында — 10 меңгә кадәр (аерым чорларда — 16 меңгә кадәр), дары з-дында — 9 меңгә кадәр, Шабановның формалы кием ф-касында — 8 меңгә кадәр, Крестовниковлар пр-тиеләрендә 2 меңгә кадәр кеше эшли. Сугыш елларында Казан губернасының сәнәгать эшчеләре составында хатын-кызлар күбәя — 1914 тә алар 27,7% булса, 1916 да 41,4% тәшкил итә.

Сугыш елларында икътисадның милитаризацияләнүе корал һәм сугыш кирәк-яраклары җитештерүче пр-тиеләрнең чиктән тыш үсүенә китерә. Хәрби өлкә һәм халык ихтыяҗлары өчен җитештерү арасындагы ярашмаучанлыкны дәүләт органнары (махсус киңәшмәләр һ.б.) тарафыннан чималны, ягулыкны, җиһазларны, транспорт чараларын, эшче көчне һәм азык-төлекне базардан тыш бүлү юлы б-н хәл итү омтылышлары илдә якынлашып килгән социаль-икътисади кризисны булдырмый кала алмый. Социаль-икътисади киеренкелек Россия армиясенең җиңелүләре б-н кискенләшә, ахыр чиктә 1917 елгы *Февраль революциясенә* китерә; рев-циядән соң Казан губернасында эшчеләр хәрәкәте сизелерлек җанлана. Апрель-май айларында сәнәгать пр-тиеләренең күпчелегендә эшчеләр үз ихтыярлары б-н 8 сәгатьлек эш көне, җитештерү һәм товарларны бүлү өстеннән үз контрольләрен урнаштыралар, фабрика-завод ком-тлары оештыралар. Эшчеләрнең хәле, кыска вакытта гына яхшырганнан соң, икътисади бөлгенлек нәтиҗәсендә кабат авырлаша. Сәнәгать товарларына бәяләр арту хезмәт хакы үсешен күпкә узып китә. Күп кенә пр-тиеләр ябыла, *эшсезлек* үсә. Әлеге шартларда эшчеләр массаларының сәясиләшү процессы тизләнә. 1917 нең октябрендә, хәрби гарнизон солдатлары б-н бергә, эшчеләр Казанда һәм губернада совет хакимияте урнаштыруда актив катнашалар (к. *Казанда 1917 елгы Октябрь кораллы баш күтәрелеше*).

Большевиклар хакимияткә килгәннән соң Э.с. җәмгыятьнең җитәкче көче (гегемоны) дип белдерелә, ләкин тоталитар система шартларында ул үз мәнфәгатьләрен реаль чагылдыру һәм яклау мөмкинлекләреннән мәхрүм ителә; илдә акрынлап «хәрби-коммунистик» диктатура урнаша. *Гражданнар сугышы* елларында Казан губернасы эшчеләреннән төрле хәрби берәмлекләр оештырыла, алар Кызыл һәм Ак армияләрнең сугыш хәрәкәтләренә актив тартылалар. *«Хәрби коммунизм»* сәясәтен гамәлгә ашыру чорында Э.с. вәкилләре губерна азык-төлек әзерләү органнары эшендә (к. *Продразверстка*), банкларны сәнәгать һәм сәүдә пр-тиеләрен *национализацияләүдә* катнашалар. Национализацияләү барышында эшчеләр формаль рәвештә фабрикалар һәм заводларның хуҗаларына әверелә ләр, пр-тиеләрдә эшчеләр контроле урнаштыралар. Хосусый пр-тиеләрнең Э.с. «кулына» күчүе моңарчы губерна икътисадының төп тармаклары, сәнәгать һәм а.х. арасында яшәп килгән икътисади элемтәләрне тарката, аларда кризислы күренешләрне көчәйтә. Сәнәгатьне киң колачлы национализацияләү пр-тиеләрнең бер өлеше ябылуга һәм Э.с. санының кимүенә китерә. 1918 дә сәнәгать эшчеләренең саны 11 меңнән артык кешегә кими. Бер үк вакытта эшсезлек үсә: 1918 нең маенда исәптә торучы эшсезләрнең саны 13253 кешегә кадәр арта. Эшсезлекне киметү максатында 1920 дән башлап эшчеләрне актив рәвештә төрле торгызу эшләрендә һәм илдәге удар төзелешләрдә (Екатеринбург, Ижевск, Сормово з-длары һ.б. пр-тиеләр), Донбасс шахталарында, Грозный нефть промыселларында (7,5 меңләп кеше), тимер юлларда (17640 кеше) файдалана башлыйлар. Гражданнар сугышы елларында Э.с.ның сыйнфый йөзен югалту процессы кискен көчәя, эшчеләр, дистәләрчә һәм йөзләрчә кешелек төркемнәр булып, заводлардан һәм фабрикалардан китәләр, тамак туйдыру өмете б-н авылларга юнәләләр. Сугышка кадәрге чор б-н чагыштырганда, Казанда сәнәгать эшчеләренең 52% ы кала, аларның да яртысына гына дәүләт фондыннан азык-төлек паеклары бирелә. 1921 нең мартында *яңа икътисади сәясәткә* (нэп) күчү б-н сәнәгатьтә ведомство реструктуризациясе һәм өлешчә хосусыйлаштыру уздырыла. 1922–23 тә Татарстан икътисадын торгызу башлана. Нэпның базар механизмнары Э.с. хәлендә уңай чагыла башлый. 1926 да халык санын алу мәгълүматлары буенча, респ-када 35 меңләп эшче исәпләнә, шулардан 16,9 меңгә якын кеше цензлы сәнәгатьтә эшли. Фабрика-завод эшчеләренең гомуми исәбендә текстильчеләр — 2578, металл эшкәртү тармагындагылар — 2203, күнчеләр — 1146, химия пр-тиеләрендә эшләүчеләр — 819, азык-төлек җитештерүчеләр 767 кеше тәшкил итә. Сәнәгать Э.с.ның 27,3% ы авыр сәнәгать тармакларында эшли. Җенес һәм яшь буенча Э.с. составы үзгәреш кичерә. Эшчеләрнең металл эшкәртүчеләр, химия тармагында эшләүчеләр һәм текстильчеләр кебек һөнәри отрядларында 1,5 меңнән артык хатын-кыз исәпләнә. Җитештерүдә үсмерләр хезмәтен файдалану кискен кими. 1920 еллар Татарстанда милли эшче кадрларның тиз формалашуы һәм үсеше б-н сыйфатлана. 1925 нең ахырына респ-каның эре сәнәгатендә Э.с.нда татарларның чагыштырмача өлеше 25,1% ка кадәр арта. 1926 да респ-када 7905 татар эшчесе (ш.и. 1671 хатын-кыз) исәпләнә, шулардан 3490 кеше (643 хатын-кыз) фабрика-завод сәнәгатендә эшли. Тулы булмаган мәгълүматлар буенча, 1926 ның ахырына СССРда 99,5 мең татар эшчесе исәпләнә. Мәгълүматлар бирелгән 55977 кешедән 15903 кеше фабрика-завод сәнәгатендә мәшгуль була. 1928 дә респ-када сәнәгать эшчеләренең саны рев-циягә кадәрге күрсәткечкә тиңләшә.

1920 елларның 2 нче яртысында — 1930 елларда Татарстан халык хуҗалыгында тизләтелгән индустрияләштерү башлангач, Э.с.ның сыйфат һәм сан составында шактый зур үзгәрешләр була. Индустрияләштерү елларында Э.с. башлыча авыллардан кайткан элеккеге пролетарий, кустарьлар, һөнәрчеләр кадрлары, шәһәрләрдә яшәгән эшсезләр, *крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерүдән* һәм *кулакларны йорт-җирләреннән куудан* качкан батраклар һәм авыл кешеләре (колхозчылар, аерым хуҗалык ияләре, таза тормышлы крәстияннәр, адм. мәхрүм ителгәннәр) хисабына тулылана. 1926–28 дә сәнәгатькә һәм төзелешкә 20 меңнән артык эшсез җибәрелә. 1930 да Татарстанда хезмәт биржасы ябыла, рәсми рәвештә эшсезлекнең бетерелүе хакында игълан ителә. Э.с. сафлары ш.у. укучы яшьләр хисабына тулылана, алар өчен һөнәри-техник белем бирү курслары һәм мәктәпләре оештырыла. 1932 нең 1 декабренә ФЗУларда һәм алар тибындагы уку йортларында 8271 кеше (ш.и. 31,3% — эшчеләр балалары, 41% — колхозчылар балалары) укый. 1932–35 тә ФЗУлар 10 мең яшь эшче әзерли. Моннан тыш, яшьләрнең бер өлеше җитештерүдә техник уку уза (1931 дә фабрикаларда һәм заводларда 2,7 мең кеше укый). 1937 нең 1 гыйнварына Татарстан җирле сәнәгатендә квалификацияле эшчеләр 53,3% тәшкил итә. Татар эшчеләренең 50% тан артык өлеше квалификация ала. 1940 ка эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең тулай саны 367,9 мең кешегә, ш.и. сәнәгать җитештерүендә 133,1 мең кешегә җитә. 1939 да респ-ка халкы структурасында сәнәгать эшчеләренең һәм хезмәткәрләрнең өлеше 35,2% тәшкил итә (1926 да — 2,1%).

Индустрияләштерү елларында Татарстан эшчеләре һәм крәстияннәре массачыл рәвештә илнең зур төзелешләренә китә башлыйлар. 1931 дә генә дә Донбасска, Уралга һәм илнең башка төбәкләренә — 125 меңләп, 1939 ның май-сентябрь айларында — 21320 (ш.и. күмер сәнәгатенә — 13957), 1941 нең гыйнвар-июнь айларында 28000 нән артык кеше җибәрелә. Нәтиҗәдә әлеге төбәкләрдә татар эшчеләренең яңа һөнәри отрядлары оеша башлый, татар халкы тупланып яшәгән җирләрдә туган телдә вакытлы матбугат чыгарыла (*«Донбасс эшчесе»*, *«Пролетар»*, *«Тау эше техникасы»* һ.б.). 1939 да халык санын

алу мәгълүматлары буенча СССРда 502 меңнән артык, ш.и. РСФСРда 422 меңләп татар эшчесе исәпләнә.

*Бөек Ватан сугышы* елларында Татарстан Кызыл Армиянең тыл базасына әверелә. Сәнәгатьне көнбатыштан көнчыгышка эвакуацияләү нәтиҗәсендә респ-ка Э.с.ның чагыштырмача өлеше шактый арта. Сугышның беренче елларында респ-ка терр-ясендә 70 тән артык эвакуацияләнгән пр-тие (76 мең эшче) урнаштырыла һәм файдалануга тапшырыла. Сугыш чорында сәнәгатькә Казанның эшкә сәләтле халкыннан 15 меңләп кеше җибәрелә. Э.с. сафларын тулыландыруда 1940 та оештырылган дәүләт хезмәт резервлары системасы уч-щеләре һәм мәктәпләре зур роль уйный. Сугыш елларында 220 меңләп кеше, ш.и. хезмәт резервы уч-щеләре һәм мәктәпләре тарафыннан 53 белгечлек буенча 52,1 мең эшче әзерләнә һәм яңадан әзерләп чыгарыла. Сугышның соңгы елларында җитештерүдә индивидуаль-бригада алымы б-н укыту киң җәелдерелә, әлеге алым яңа эшчеләрнең 85% ын колачлый. Сугыш чорында Э.с.ның һөнәри составы да үзгәрә, аның нигезен оборона сәнәгатендә эшләүче эшчеләр тәшкил итә. 1941–45 тә, эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне хәрәкәттәге армиягә күпләп мобилизацияләүгә карамастан, 1940 ел б-н чагыштырганда, сәнәгатьтә, төзелештә һәм транспортта аларның саны 16% ка арта. Фронтка киткән квалификацияле эшчеләргә алмашка хатын-кызлар һәм үсмерләр килә. 1941–44 тә респ-каның сәнәгать пр-тиеләрендә эшләгән хатын-кызларның чагыштырмача өлеше 33,1% тан 53,8% ка кадәр үсә. Эшчеләрнең 40–50% ын яшьләр тәшкил итә. Патриотизм, иҗтимагый һәм хезмәттәге активлык нәтиҗәсендә, бигрәк тә хәрби сәнәгатьтә, хезмәт җитештерүчәнлеге арта. Күп кенә эшчеләргә тәүлеккә 12–14 сәгать эшләргә туры килә. Стахановчылар һәм җитештерү новаторлары хәрәкәтләре активлаша. Татарстан эшчеләре хезмәттәге казанышлары өчен СССРның 606 ордены һәм 599 медале б-н бүләкләнә.

Сугыш тәмамланганнан соң Татарстанда кабат Э.с.ның саны арта башлый. 1950 еллар башына Э.с.ның квалификация һәм яшь составы торгызыла. Респ-ка Э.с. тулылануның төп формалары оештырып җыюдан, пр-тиеләр тарафыннан туплаудан, иҗтимагый чакырудан гыйбарәт була. Элеккечә үк крәстияннәр Э.с. сафларын туплауның иң зур чыганагы булып кала; крәстияннәр пр-тиеләрнең һәм оешмаларның колхозлар һәм совхозлар б-н төзелгән шартнамәләре нигезендә сәнәгый җитештерүгә китәләр. 1939 да һәм 1959 да халык санын алу мәгълүматлары буенча, Татарстандагы шәһәр халкының саны 614,3 меңнән 1190,3 мең кешегә кадәр арта, авыл халкы саны, кимеп, 2299,9 мең кешедән 1660,1 мең кешегә кала. 1950 елларда кәсепләр кооперациясе пр-тиеләре бетерелү нәтиҗәсендә Э.с. ш.у. кооператив артельләр хезмәткәрләре хисабына тулылана (к. *Кооперация*). Э.с. сафларын тулыландыруда дәүләт хезмәт резервлары системасының Татарстан терр. идарәсе карамагындагы ФЗӨ һөнәрчелек, тимер юллар техник уч-щеләре һәм мәктәпләре зур роль уйный, алар 1946–58 дә сәнәгатьнең төрле тармакларына 63 меңнән артык белгеч әзерләп җибәрәләр. Бер үк вакытта Э.с. составы урта мәктәпләрне тәмамлап, җитештерү курсларында, максатка билгеләнгән һәм техминимум мәктәпләрендә, бригадада һәм индивидуаль укыту процессында эшче белгечлекләр алган затлар хисабына тулылана. 1958 гә укытуның әлеге формалары 40 меңнән артык яшь эшчене колачлый. 1960 та сәнәгатьнең төрле тармакларында 287,1 мең эшче (Татарстан халык хуҗалыгында мәшгуль халыкның 28% ы) эшли. Э.с. структурасында да сыйфат үзгәрешләре була. 1940 ел б-н чагыштырганда, 1958 дә җиңел сәнәгатьтәге эшчеләрнең саны 25,1% тан 17,5% ка кадәр, урман һәм агач эшкәртү сәнәгатендә 20% тан 14,7% ка кадәр кими. 1950–58 дә химия сәнәгатендә эшләүчеләр саны — 2 тапкыр диярлек, машиналар төзелеше һәм металл эшкәртү пр-тиеләрендә — 2 тапкырдан күбрәккә, төзелеш тармагында — 3 тапкырдан күбрәккә, текстиль индустриясендә 2 тапкыр диярлек арта. Сугыштан соңгы елларда Э.с.ның яшь составы шактый зур үзгәрешләр кичерә, 40 яшькә кадәрге эшчеләрнең чагыштырмача өлеше күпкә арта. 1958 дә ул төзелеш пр-тиеләрендә — 84%, нефть сәнәгатенең бораулаучы пр-тиеләрендә — 87%, нефть чыгару индустриясендә — 86%, машиналар төзелеше, металл эшкәртү һәм төзелеш материаллары пр-тиеләрендә 80% тәшкил итә. 1947–58 дә стажы 10 елга кадәрге эшчеләр саны 90% тан 58% ка кадәр кыскара. Әлеге елларда җенес буенча да Э.с. составы үзгәрә: хатын-кыз эшчеләр саны 64% тан (1946) 51,3% ка кадәр (1958) кими. 1958 дә эшчеләрнең тулай исәбендә хатын-кызлар өлеше химия сәнәгатендә — 57%, җиңел сәнәгатьтә — 78% тан артык, текстиль сәнәгатендә — 72%, машиналар төзелеше һәм металл эшкәртүдә — 44%, нефть чыгару индустриясендә 27% тәшкил итә. Эшчеләрнең милли составы да үзгәреш кичерә — 1958 дә сәнәгатьтәге барлык эшчеләрнең 32% ка кадәрге өлеше татарларга туры килә. Сугыштан соңгы чорда төп закончалык Э.с.ның саны, хезмәткәрләрнең башка категорияләре арасында фабрика-завод эшчеләренең чагыштырмача өлеше артудан гыйбарәт була. 1959 да халык санын алу мәгълүматлары буенча, СССРда — 1,1 млн.нан артык, ш.и. РСФСРда 910 меңнән артык татар эшчесе исәпләнә. Эшчеләр саны буенча татарлар СССРда руслар, украиннар һәм белоруслардан соң 4 нче, РСФСРда руслардан соң 2 нче урынны били.

1960–80 елларда җитештерүгә *фәнни-техник революция* (ФТР) казанышларын кертү чорында Татарстан Э.с. төп отрядларының, бигрәк тә оборона пр-тиеләрендә эшләгән өлешенең һөнәри асылы шактый үзгәрә. Э.с.ның тармак, һөнәри һәм квалификация составында зур үзгәрешләр була. Техник алгарыш җитештерүнең автоматлаштырылуы һәм җитештерү циклларының комплекслы механикалаштырылуы б-н бәйле эшче профессияләр җыелмасының артуына, ш.у. авыр кул хезмәте башкаручылар санының кимүенә китерә. Сәнәгатьнең төрле тармакларының җитештерү-техник базасы халәтенә принципиаль үзгәрешләр керткән һәм эшчеләрнең һөнәри составы камилләштерелүгә сәбәп булган индустриаль һәм фәнни-техник алгарыш үз хезмәтләрендә акыл эшчәнлеген һәм физик эшчәнлекне берләштергән югары квалификацияле хезмәткәрләр төркеме барлыкка килүгә этәрә. 1960 еллар ахырында әлеге төркемнең чагыштырмача өлеше Татарстан Э.с.ның 2% ыннан артмый. ФТР, һөнәри белемнәргә, оештыру сәләтләренә, ш.у. хезмәт ияләренең гомуми мәдәни һәм интеллектуаль үсеш дәрәҗәсенә карата арта барган таләпләр куеп, төп җитештерүче көчнең — эшчеләрнең һәм инженер-техник кадрларның җитештерү һәм вазифалары асылын тамырдан үзгәртү өчен алшартлар тудыра. Хезмәткәрләр квалификациясен күтәрү һәм үзгәртү максатында, бигрәк тә хезмәтнең аеруча интенсив үсеш кичергән өлкәләрендә, вакыт-вакыт яңадан әзерләү ихтыяҗы барлыкка килә. Татарстанда бу тенденция СССР МСның «Һөнәри-техник белем бирү системасы уку йортларында квалификацияле эшчеләр әзерләүне алга таба яхшырту чаралары турында» (1969) һәм «Һөнәри-техник белем бирү системасын алга таба яхшырту турында» (1972) карарлары кабул ителгәннән соң үсеш ала. 1980 нең ахырына Татарстанда Э.с.ның һөнәри отрядларын әзерләүдә һәм яңадан әзерләүдә һөнәри-техник белем бирү системасының 116 уч-щесе катнаша, алар квалификацияле эшче кадрларга булган ихтыяҗның 20% тан артыгын тәэмин итәләр. Ш.у. җитештерүдә укыту-өйрәтүнең төрле формалары файдаланыла. КамАЗ һәм Түбән Кама нефть химиясе пр-тиеләре комплексы төзелеше вакытында 1970–78 дә «Камгэсэнергострой» идарәсенең уку-укыту комб-тында (Чаллы ш.) 50 мең төзүче әзерләп чыгарыла. Ел саен 1 меңнән артык төзүче әзерләгән шундый ук комб-т Түбән Камада эшли. 1974–78 дә Түбән Кама шин з-дында төрле белгечлекләр буенча 12 меңләп эшче әзерләнә. Яңа кадрларның зур өлешен колхоз крәстияннәре тәшкил итә; алар, 1970 елларның 2 нче яртысында авылларда яшәүчеләргә тулысынча паспортлар бирелүдән файдаланып, авыл җиреннән яңа төзелүче шәһәрләргә күченеп киләләр, эшчеләрнең яңа отрядларын хасил итәләр. Татарстан вәкилләреннән тыш, алар арасында илнең башка респ-каларыннан һәм өлкәләреннән чыгучылар була. КамАЗның автомобильләр төзүче эшчеләр әзерләүче уку-укыту базалары Автомобиль сәнәгате министрлыгының барлык эре пр-тиеләрендә (СССРның 26 шәһәрендә) оештырыла. КамАЗ өчен югары квалификацияле белгечләрне «АвтоЗИЛ» һәм «Россельмаш» пр-тиеләре каршындагы югары техник уку йортлары әзерли. Нәтиҗәдә, 1978 нең ахырына КамАЗга 7 меңнән артык белгеч килә. Төрдәш пр-тиеләрдә 20 меңләп эшче уку-өйрәнү уза. Бер үк вакытта, 1970–78 дә, КамАЗда 60 мең эшче квалификацияләрен күтәрә. Эшчеләр квалификациясен күтәрү системасын даими камилләштерү,

социаль һәм техник алгарыш Э.с.ның шактый дәрәҗәдә сыйфат ягыннан үсешенә китерә. 1980 еллар башына Татарстан эшчеләренең 90% тан артык өлеше югары, урта һәм тәмамланмаган урта белемгә ия була. 1946 ел б-н чагыштырганда, 1989 га сәнәгатьнең төрле тармакларында эшчеләр саны — 4,5 тапкыр, төзүчеләр — 9,7 (16,8 мең кешедән 226,1 мең кешегә кадәр), транспортчылар — 3,7 (32,5 меңнән 116,9 меңгә кадәр), хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәрләренең исәбе 3,6 тапкыр күбәя. Татарстан Э.с.ның тулай исәбе 4,3 тапкыр арта. 1989 да Татарстанда 1,62 млн эшче һәм хезмәткәр (шулардан 582,4 мең кеше сәнәгатьтә эшли), ш.и. 734,4 мең татар эшчесе (эшләүчеләрнең тулай исәбеннән 45%) исәпләнә. Татар эшчеләре а.х.нда — 56%, транспортта — 46%, төзелештә — 45%, сәнәгатьтә 41% тәшкил итәләр. Э.с. һәм хезмәткәрләр структурасында хатын-кызлар 53,3% били.

1980 еллар ахырында — 1990 еллар башында Татарстан икътисадындагы кардиналь институциональ һәм структур үзгәрешләр эшче көчкә ихтыяҗ кимүнең һәм шуның нәтиҗәсендә эшче һөнәрләрнең дәрәҗәсе төшүнең төп сәбәпчесе була. 1990 еллар башында җиңел һәм авыр (оборона) сәнәгатьтә эшче кадрлар саны аеруча сизелерлек күләмдә кими. 1990 елларда әлеге тармакларда җитештерү тиңдәшле рәвештә 71% һәм 67% тәшкил итә. Сәнәгать пр-тиеләрендә эшчеләр саны 397,6 мең кешегә кадәр азая (1998). Әлеге факторлар тәэсирендә респ-ка икътисади секторының төрле тармаклары арасында мәшгуль халыкның кабат бүленүе гамәлгә ашырыла. Хезмәт күрсәтүләр һәм сәүдә, бигрәк тә базар инфраструктурасы б-н бәйле тармакларда — арадашчылык һәм финанс-кредитлау эшчәнлегендә, ш.у. сәнәгатьнең нефть һәм газ чыгару тармакларында эшләүчеләр саны тотрыклы рәвештә арта. Гомуми алганда, 1990 елларда хезмәт базары кадрларның гаять хәрәкәтчәнлеге б-н сыйфатлана. Эшчеләр саны кимүнең төп сәбәбе — аларның үз теләкләре б-н эштән чыгуы. Штатлар кыскару сәбәпле, хезмәттән китү очраклары аз була, чөнки азат ителүче хезмәткәрләргә законнарда каралганча матди ярдәм күрсәтү өчен мөмкинлекләр булмау сәбәпле пр-тиеләр эштән җибәрүнең андый формасын кулланмыйлар. Шул ук вакытта Татарстан пр-тиеләрендә адм. инициативасы б-н түләүсез яки өлешчә түләүле мәҗбүри ялга җибәрү гамәлгә ашырыла, шул сәбәпле респ-када кабат эшсезлек барлыкка килә, 1990 еллар башында эшсезләрне теркәү янә гамәлгә кертелә. Вазгыятьне үзгәртү максатында төрле алымнар — җитештерүне киңәйтү һәм эшчәнлекнең яңа өлкәләрендә эш урыннары булдыру, ташламалы кредитлау яки сәнәгать пр-тиеләренә салым ташламалары бирү, пр-тиеләрнең тулы булмаган эш атнасына күчүе, пенсия яшен катгый билгеләү яки закон тарафыннан билгеләнгән пенсия яшен киметү хисабына эшчеләр көчен тәкъдим итүне азайту, керем алу күздә тотылмаган вакытлыча эш урыннары булдыру (җәмәгать эшләре), эшчеләрне яңадан әзерләү һәм аларның һөнәри квалификациясен күтәрү кулланыла. 1990 еллар ахырында — 2000 еллар башында Татарстанда сәнәгать җитештерүе өлкәсендә сәясәтне алыштыру (базар мөнәсәбәтләренә «йомшак керү», кризис шартларында җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрү, югары өстәмә бәяле көндәшлеккә сәләтле продукция булдыру максатларында пр-тиеләргә ярдәм итүдән аларның инновацион үсешен стимуллаштыруга күчү һ.б.) сәнәгатьнең стратегик яктан мөһим тармакларында кризис күренешләрен җиңеп чыгуга, респ-ка халкының мәшгульлеген арттыруга һәм эшчеләр арасында эшсезлекне киметүгә мөмкинлек бирә. 2006 да Татарстанда сәнәгать җитештерүендә 420 мең чамасы кеше, яки респ-када барлык эшләүчеләрнең 23,3%ы мәшгуль була. Хәзерге вакытта татар эшчеләренең аеруча зур төркемнәре Мәскәүдә, С.-Петербургта, Идел буе, Урал, Себер, Украина шәһәрләрендә яши. 21 йөз башына БДБ илләренә 1 млн.лап татар эшчесе исәпләнә. Ш.у.к. *Сәнәгать*, *Авыл хуҗалыгы*.

*Әд.:* к. *Индустрияләштерү*, *Сәнәгать мәкаләләре*.

*Р.В.Шәйдуллин.*

# Ю

**ЮБИЛЕ́Й А́РКАСЫ** («Кызыл капка») Казанда, монументаль архит-ра истәлеге. Дары бистәсенең уртасында Дары з-дына төп керү юлында (хәзерге Р.Петров паркына төп керү урыны) төзелә. Ю.а. арх. И.П.Котелов проекты буенча 1888 елда заводның йөз еллыгы уңае б-н куела, өч өлештән тора, урта өлешенең биеклеге 12 *м.* Аңа ике яклап һәрберсенең биеклеге 6 *м* булган 2 җәяүлеләр а́ркасы кушып салына. Үзәк а́рка стильләштерелгән тоскан ордеры ярымколонналарына утыртылган киң архивольт б-н каймалана.



Юбилей а́ркасы. 1888. Архитекторы И.П.Котелов. Гомуми күренеше.

Архиволька рус телендә «Казан казна заводы» дип чокып язылган. Капканың өске өлеше профильле кәрнизләр һәм чыгынтылы аттиклар б-н төгәлләнә. А́ркалар тирән итеп рустланган пилястралар б-н бизәлә. Үзәк өлеш фризындагы картушларда заводның нигезләнү һәм юбилей еллары күрсәтелә (1788–1888). Тимпанда Екатерина II һәм Александр III нең кабарынкы итеп эшләнгән вензельләре куела. А́рка дары ядрәләре һәм туп көпшәләреннән корылган, иң өскә лавр яфракларыннан үрелгән такыя куелган пирамида рәвешендәге композиция б-н очлана. Ю.а.ның төсләр чишелеше диварларның кызыл кирпеч төсендә («Кызыл капка» дигән икенче атамасы шуңа бәйле) һәм детальләрнең ак төстә булуыннан гыйбарәт. Гомумән, а́рканың бизәлеше классицизм юнәлешенең эклектика стилендә башкарыла. 1988 дә Ю.а. төзекләндерелә һәм анда совет чорында юкка чыгарылган тарихи детальләр торгызыла.

*Әд.:* Памятники истории и культуры в Казани. К., 1982. *Х.Г.Надыйрова.*

**ЮБИЛЕ́Й МӘЧЕТЕ́**, к. *Ислам кабул итүнең меңьеллыгы шәрәфенә салынган мәчет.*

**«ЮБИЛЕ́ЙНАЯ»**, кура җиләге сорты. 1969 елда Татарстан Респ-касы а. х. тәҗрибә станциясендә Н.И.Вакуленко һәм А.А.Надысева тарафыннан чыгарыла. Кышка чыдам сорт, өлгерү вакыты уртача. Куаклары биек, көчле, туры. Аз чәнечкеле, яфраклары уртача зурлыкта, уртача җыерчыклы, яшел, төкле, аз бөтерчекләнгән, балавыз куныклы. Җиләкләре эре, кызыл, конуссыман, әчкелтем-баллы; яңа өлгергән һәм эшкәртелгән килеш куллanyла. Күчереп йөртүне яхшы кичерә. Татарстанда бу сорт 1974 тән районлаштырыла. Коллектив һәм йорт янындагы бакчаларда үстерелә.

*Әд.:* Маненков К.С., Кривоногова А.Г. Ягодные культуры. К., 1985.

**«ЮБИЛЕ́ЙНАЯ»**, Лаеш р-ныңдагы кошчылык ф-касы. 1981 елда оештырыла. Үзәк утары — Габишев посёлогы. 2001 дән АҖ. А.х. житештерүендә эшләүчеләр саны 415 кеше (2018). 2013 тән «Ак Барс» кошчылык комплексы ҖЧҖнең Лаеш ф-лы. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре — йомырка һәм кош ите җитештерү. 2018 нең 1 гыйнварына кошларның баш саны 3155,8 мең тәшкил итә, ш.и. йомырка салучылары — 1902,5 мең баш. Йомырка салучанлык 331,8 данә (2017). 615,9 млн. данә йомырка, 1290,9 тонна ит җитештерелә. Хуҗалыкта 4 ярусллы технол. җиһазлар үзләштерелә, 2009 ел б-н чагыштырганда, бу 2017 дә йомырка салучы тавыкларның баш санын 39,2% ка арттырырга мөмкинлек бирә.

Җитәкчеләре: К.А.Деревянкин (1981–85), Б.А.Шәмгунов (1985–88), Н.Б.Рымар (1988–2003), М.Н.Моталимов (2003–09), М.Ш.Сөнгатов (2009–12), Р.С.Хисмәтуллин (2012–2016), Ф.Г.Нигъмәтуллин (2016 дан). *И.Н.Афанасьев.*

**ЮВА́С** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 36 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасыннан 2,5 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 125 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Битоман по речке Юван исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстиянннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, тимерче алачыгы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 745,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 72 ир-ат; 1859 да — 401, 1897 дә — 545, 1908 дә — 578, 1920 дә — 598, 1926 да — 669, 1938 дә — 659, 1949 да — 497, 1958 дә — 346, 1970 тә — 266, 1989 да — 151, 2002 дә — 146 кеше.

**ЮГА́Н** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 34 *км* көнбатыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 19 кеше (чуашлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оешкан көненнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1949 да — 116, 1958 дә — 320, 1970 тә — 177, 1979 да — 111, 1989 да — 51, 2002 дә — 35 кеше.

**ЮГАРЫ́ АКТА́Ш** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 14 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чаллы — Әлмәт автомобиль юлы буенда. 2010 елда 822 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Ашлык әзерләү һәм эшкәртү пр-тиесе. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мордва Акташы исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстиянннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.А.та Никола чиркәве (1880 дә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1882 дә ачыла), 2 ашлык саклау-сату кибете, 2 су тегермәне, тимерче алачыгы, шәраб һәм 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4435 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 233, 1795 тә — 291 ир-ат; 1859 да — 1109, 1884 тә — 1734, 1897 дә — 1975, 1913 тә — 2669, 1920 дә — 2747, 1926 да — 2149, 1938 дә — 1542, 1949 да — 1228, 1958 дә — 1192, 1970 тә — 1302, 1989 да — 837, 2002 дә — 839 кеше.

**ЮГАРЫ́ АКХУҖА́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 34 *км* төньяктарак, Казан — Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 135 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 гә кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.А.да җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 938,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ивановка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартын-

нан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 17 ир-ат; 1859 да — 284, 1897 дә — 624, 1908 дә — 770, 1926 да — 541, 1938 дә — 403, 1949 да — 270, 1958 дә — 214, 1970 тә — 176, 1979 да — 182, 1989 да — 146, 2002 дә — 164 кеше.

**ЮГАРЫ́ АРБА́Ш** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 26 *км* көньяктарак, Баш-Арбаш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 283 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1619 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, ияр ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.А.та мәчет, мәктәп, су тегермәне, тимерче алачыгы, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 900,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 мартыннан — Тәкәнеш, 1961 дән — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 53 ир-ат; 1859 да — 373, 1897 дә — 697, 1908 дә — 749, 1920 дә — 683, 1926 да — 696, 1949 да — 504, 1958 дә — 444, 1970 тә — 496, 1979 да — 408, 1989 да — 321, 2002 дә — 319 кеше.

**ЮГАРЫ́ АТЫ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 13 *км* төньяк-көнбатыштарак, Аты елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 231 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Аты исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чыпта, киндер сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.А.да мәчет, җил һәм су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1597,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 198 ир-ат; 1859 да — 827, 1897 дә — 887, 1908 дә — 933, 1920 дә — 852, 1926 да — 821, 1938 дә — 730, 1949 да — 443, 1958 дә — 367, 1970 тә — 321, 1979 да — 276, 1989 да — 231, 2002 дә — 240 кеше.

**ЮГАРЫ́ ӘЗӘ́К** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 15 *км* төньяктарак, Ия елгасы буенда. 2010 елда 128 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Әзәк-Яваш исеме б-н дә билгеле. Халкы 17 йөз башында христиан динен кабул итә, 1870 елларда исламга кире кайта. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында алар дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү һәм киндер сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Ә.тә мәчет, мәктәп, 3 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 621,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир-ат; 1859 да — 319, 1897 дә — 495, 1908 дә — 616, 1920 дә — 617, 1926 да — 558, 1938 дә — 345, 1949 да — 251, 1958 да — 189, 1970 тә — 186, 1979 да — 195, 1989 да — 136, 2002 дә — 141 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

**ЮГАРЫ́ ӘЛКИ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 19 *км* көньяктарак, Ата елгасы буенда. 2010 елда 276 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөз уртасында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.Ә.дә мәчет эшли. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп, 5 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2090,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Түбән Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 108 ир-ат; 1859 да — 767, 1897 дә — 1008, 1908 дә — 1189, 1926 да — 729, 1938 дә — 879, 1949 да — 718, 1958 дә — 868, 1970 тә — 692, 1979 да — 579, 1989 да — 413, 2002 дә — 370 кеше.

**ЮГАРЫ́ ӘЛМОРЗА́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 33 *км* көньяктарак, Юхмачы елгасы буенда. 2010 елда 374 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Әлморза исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.Ә.да мәчет һәм мәктәп эшли. 20 йөз башында 2 тегермән, 2 вак-төякләр кибете эшли. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Успение-Юхмачы волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 64 ир-ат; 1859 да — 438, 1897 дә — 662, 1908 дә — 788, 1926 да — 550, 1938 дә — 518, 1949 да — 552, 1958 дә — 571, 1970 тә — 807, 1979 да — 723, 1989 да — 518, 2002 дә — 434 кеше.

**ЮГАРЫ́ ӘРНӘ́Ш** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 59 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 91 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1619 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Казаклар исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы (керәшен татарлар) дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз башыннан Ю.Ә.тә татарлар б-н бергә руслар да яши. 1871–76 да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе эшли. 20 йөз башында ярма яргыч, вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 722,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 253, 1897 дә — 496, 1908 дә — 548, 1920 дә — 497, 1926 да — 556, 1938 дә — 486, 1949 да — 252, 1958 дә — 344, 1970 тә — 345, 1979 да — 288, 1989 да — 213, 2002 дә — 121 кеше.

**ЮГАРЫ́ ӘШНӘ́К** посёлогы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әшнәк елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда даими яшәүчеләр юк. 1910 елларда нигез салына. Башта Казан губернасының Лаеш өязе Анатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1920 дә — 94, 1926 да — 128, 1949 да — 165, 1958 дә — 105, 1970 тә — 72, 1989 да — 33, 2002 дә — 14 кеше.

**ЮГАРЫ́ БАГРА́Ж** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 21 *км* көнчыгыштарак, Баграж елгасы (Урман Зәенең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 236 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1676 дан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, вак һөнәрчелек: тәгәрмәч, чана, дуга бөгү, чабата үрү, чыпта һәм киндер сугу б-н шөгыльләнә. Ю.Б. авылы халкы 1773–75 еллардагы Крәстияннәр күзгалышында, 1905–07 еллардагы баш күтәрүләрдә актив катнаша. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, авылда су тегермәне эшли. 1889 да сәүдәгәр И.Г.Стахеев иганәсенә Троица чиркәве төзелә, 1897 дә чиркәү-приход мәктәбе ачыла. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1404 дис. тәшкил итә. 1931 дә Ю.Б.да «Путь Ленина» к-зы оештырыла, 1959 да ул Вахитов исем. колхоз, 1970 тән «Үрнәк» с-зы, 1991 дән «Баграж» с-зы (1998 дән а.х. товарлары җитештерү кооперативы) составына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февразен-

нән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 390, 1897 дә — 903, 1926 да — 1098, 1938 дә — 982, 1949 да — 717, 1958 дә — 610, 1970 тә — 498, 1979 да — 333, 1989 да — 222, 2002 дә — 236 кеше.

**ЮГАРЫ́ БАЙЛА́Р** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 28 *км* көнчыгыштарак, Тиргәвеш елгасы буенда. 2010 елда 276 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 19 йөзнең 2 нче яртысында Иске Байлар авылыннан күченүчеләр нигез сала. Халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Б.да мәчет, мәктәп, ашлык саклау-сату һәм бакалея кибете, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1398 дис. тәшкил итә. 1931 дә авылда «Чәчкәле» к-зы оештырыла, 1960 та «Ярыш» к-зы (Күзкәй а.) б-н берләшә, 1988 дән — кабат мөстәкыйль хуҗалык (хәзер «Чәчкәле» а.х. товарлары җитештерү кооперативы). 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1897 дә — 425, 1906 да — 522, 1913 тә — 636, 1920 дә — 676, 1926 да — 510, 1938 дә — 611, 1949 да — 437, 1958 дә — 555, 1970 тә — 553, 1979 да — 387, 1989 да — 252, 2002 дә — 270 кеше.

**ЮГАРЫ́ БАЛАНДА́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 7 *км* көньяктарак, Канавка елгасы буенда. 2010 елда 57 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 18 йөз уртасында чукындырылган чуашлар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Дёмкино исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Б.да чиркәү (1898 дә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2697,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Мукшы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 100 ир-ат; 1859 да — 727, 1897 дә — 1488, 1908 дә — 1691, 1920 дә — 1728, 1926 да — 1454, 1938 дә — 1094, 1949 да — 892, 1958 дә — 578, 1970 тә — 540, 1979 да — 329, 1989 да — 122, 2002 дә — 93 кеше.

**ЮГАРЫ́ БАЛТА́Й** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 22 *км* көнбатыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 197 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөзнең 1 нче яртысына кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу, агач хәзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Б.да мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 894,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 92 ир-ат; 1859 да — 508, 1897 дә — 789, 1926 да — 618, 1938 дә — 565, 1949 да — 514, 1958 дә — 382, 1970 тә — 404, 1979 да — 359, 1989 да — 299, 2002 дә — 264 кеше.

**ЮГАРЫ́ БАШЛАНГЫ́Ч УЧИ́ЛИЩЕЛӘР**, тулы булмаган урта уку йортлары, ир балалар, кыз балалар өчен һәм катнаш, 1912 елның 25 июнь Нигезләмәсе буенча оештырыла. Халык мәгарифе министрлыгы карамагында була.Уку вакыты 5 ел тәшкил итә (башлангыч мәктәптән соң). Халыкның демократик катлавы өчен билгеләнә. Ю.б.у.нең күпчелеге шәһәр уч-щеләреннән, шәһәрнең башлангыч, земствоның ике сыйныфлы һәм махсус чиркәү өч еллык мәктәпләреннән оештырыла. Ю.б.у.не тәмамлаучыларның гимназиянең җиденче сыйныфына укырга керү хокукы була, шуның б-н алар шәһәр уч-щеләреннән аерылып торалар. Авыл җирлекләрендә Ю.б.у. беренче гомуми белем бирүче урта мәктәпләр булалар. Ю.б.у.дә сыйныфлап укыту системасы хөкем сөрә, укытучылары — укытучылар ин-тларын, ш. и. *Казан укытучылар институтын* тәмамлаучылар. Казан губернасы терр-ясендә 1917 гә 19 Ю.б.у., шуларның дүртесе Казанда (Пләтән, Черек күл, Бишбалта һәм Постаучылар бистәсе; аларда 573 ир бала һәм 13 кыз бала белем ала) эшли. Совет хакимиятенең беренче елларында Ю.б.у. җирлегендә 2 нче баскыч мәктәпләр булдырыла.

**ЮГАРЫ́ БИРӘЗӘ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 10 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бирәзә елгасы буенда. 2010 елда 215 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бирәзәбаш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Б.дә мәчет (1902 дә төзелә; архит-ра истәлеге), мәдрәсә, су тегермәне, тимерче алачыгы, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1001,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 537, 1897 дә — 628, 1908 дә — 773, 1920 дә — 668, 1926 да — 796, 1938 дә — 735, 1949 да — 375, 1958 дә — 335, 1970 тә — 276, 1979 да — 241, 1989 да — 202, 2002 дә — 230 кеше.

**ЮГАРЫ́ БОГАДЫ́** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 21 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бижады елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 123 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1928 дә нигез салына. ТАССРның Минзәлә кантоны Байсар волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 203, 1949 да — 229, 1958 дә — 194, 1970 тә — 254, 1979 да — 214, 1989 да — 134, 2002 дә — 126 кеше.

**ЮГАРЫ́ БУҖА́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 4 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казансу елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 392 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 64%, руслар — 26%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, бакчачылык. Башлангыч мәктәп, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 112,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 81, 1897 дә — 90, 1908 дә — 137, 1920 дә — 94, 1926 да — 83, 1938 дә — 43, 1949 да — 158, 1958 дә — 153, 1970 тә — 189, 1989 да — 356, 2002 дә — 365 кеше.

**ЮГАРЫ́ ГӘРӘ́Й** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 44 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Гәрәй исеме б-н дә билгеле. 17–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 324 дис. тәшкил итә. 1929 да авылда «Ирек» к-зы оештырыла, 1950 дә Тельман исем. к-з составына керә. Ю.Г. башта «Агыйдел» а.х. кооперативлары берләшмәсе, хәзер «Наратлык» ҖЧҖ составында. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Такталачык волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 46, 1834 тә — 63, 1859 да — 103, 1897 дә — 126, 1913 тә — 169, 1926 да — 246, 1938 дә — 266, 1949 да — 225, 1958 дә — 210, 1970 тә — 157, 1979 да — 120, 1989 да — 78, 2002 дә — 58 кеше.

**ЮГАРЫ́ ДӘҮЛӘТЪЯ́Р** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 19 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Әшнәк елгасы буенда. 2010 елда 21 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 17 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә (дворян Ма-

нассеиннарның элеккеге крепостнойлары), игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Д.да Троица чиркәве (1904 тә төзелә; архит-ра истәлеге), су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 151 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1924 тән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 43 ир-ат; 1859 да — 349, 1897 дә — 282, 1920 дә — 365, 1926 да — 341, 1949 да — 273, 1958 дә — 228, 1970 тә — 126, 1979 да — 109, 1989 да — 60, 2002 дә — 40 кеше.

**ЮГАРЫ́ ИЯ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 46 *км* көнчыгыштарак, Ия елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 40 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Казан ханлыгы чорыннан билгеле. Крепостной хокук бетерелер алдыннан (1861), халкы алпавыт (Г.К.*Казимбәк* крепостнойлары) һәм дәүләт крепостнойлары катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.И.дә чиркәү-приход мәктәбе, 2 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 3 зур һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1155,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 28 ир-ат; 1859 да — 434, 1897 дә — 586, 1908 дә — 640, 1926 да — 826, 1938 дә — 584, 1949 да — 474, 1958 дә — 340, 1970 тә — 203, 1989 да — 57, 2002 дә — 48 кеше.

**ЮГАРЫ́ КАБА́Н** (Борисково Кабаны) күле, Казанның көньяк өлешендә, Идел буе р-нының Борисково посёлогы янында. Күл Идел елгасының югары террасалары киртләченә бик якын урнашкан. Сулык Урта Кабан күленнән 1 *км* көньяктарак һәм *Кабан күлләре* системасына керә. Түбән һәм Урта Кабан күлләренә караганда Ю.К.да су өсте тигезлеге 2 *м* га биегрәк (исеме шуннан). Су өслегенең мәйданы 25 *га*, суының күләме 1325 мең $м^3$. Озынлыгы якынча 1 *км*, киңлеге 250–300 *м*. Уртача тирәнлеге 6,5 *м*, иң зур тирәнлеге 13,7 *м*. Ю.К. казанлыгының барлыкка килүе Кабан күлләре системасының башка күлләре кебек үк, Идел елгасының элекке юлында сакланып калган, карст күренешләре б-н тирәнәйгән күл. Ю.К.ның Түбән һәм Урта Кабан күлләре б-н гидрологик бәйләнеше юк. Күлнең көньяк-көнбатыш өлешендә ермаклар бар, язгы су ташулар вакытында алар аша артык су Мирный һәм Отар посёлоклары арасында урнашкан саз-лык-күл комплексына керә. Күлнең туенуы катнаш: атм. явым-төшемнәре һәм грунт сулары исәбенә. Суы йомшак, җиңелчә минеральләшкән, гидрокарбонат-кальцийлы типта; кышын кислород кытлыгы һәм төбендә күкерт водороды булуы күзәтелә. Суының сыйфаты «уртача чисталыктагы» категориягә туры килә, әмма Кабан күлләре системасындагы күлләр арасында Ю.К. чиста күл булып санала. Ю.К.ның флора һәм фаунасы күптөрле. Альгофлорада суүсемнәрнең якынча 80 төре исәпләнелә; яр буе зонасында югары төзелешле үсемлекләрдән җикәнбаш, курак, су кәбестәсе һәм Канада элодеясы өстенлек итә. Умырткасызларның сирәк төрләреннән су чаяны һәм ранатра очрый. Күл орнитофаунасы өчен гади акчарлак, елга крачкасы, кыр үрдәге хас. Вак имезүчеләрдән ондатра яши. *Н.М.Минһаҗева.*



Югары Кабан.

**ЮГАРЫ́ КАЗАКЛА́Р** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 151 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ит терлеге асрау. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.К.да мәчет эшли. 1880 елларда авыл җәмгатенең имана җире 584,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сәрдәбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 148, 1885 тә — 198, 1920 дә — 350, 1926 да — 351, 1938 дә — 325, 1949 да — 231, 1958 дә — 145, 1970 тә — 161, 1979 да — 130, 1989 да — 138, 2002 дә — 144 кеше.

**ЮГАРЫ́ КА́МА ИҢКҮЛЕГЕ́**, Идел-Урал өлкәсе терр-ясендәге беренчел Рифей утырмаларының рифтлы (канаусыман) эре тектоник структурасы. Төньякта Тиман тау тезмәләреннән көньякта Каратауга (Көньяк Уралның көнбатыштагы тармагына) кадәр субмеридиональ юнәлештә сузыла. Көнбатыш як зонасы Татарстанның төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш өлешләрен били. Ю.К.и. як-яктан катлаулы төньяк-көнбатыш җимерелүләр системасы, субмеридиональ ашалулар б-н чикләнә һәм Урал таулары юнәлешендә (бу зонада киңлеге 250 *км* га кадәр) ята, төньяк юнәлештә 30–40 *км* га кадәр тарая. Гомуми озынлыгы 900 *км* га кадәр, көньяк өлешендә (аеруча тирән) тирәнлеге 8 *км* дан артык. Борынгы горизонтларның хәзерге структур планында күмелгән иңкүлектән тора, чикләре рифей утырмалары үсеше б-н билгеләнә. Көнбатышта Ю.К.и Татар гөмбәзе б-н чикләнә.1 млрд. ел элек, Ю.К.и. формалашканда кристаллик нигез җимерелүләре хәлиткеч роль уйный. ТРның төньяк-көнчыгыш өлешендә Ю.К.и. тирән җимерелүләр б-н чикләнгән Кама-Агыйдел авлакогеныннан тора. Минзәлә р-нындагы җимерелү алды зонасында габбро-диабазалар һәм төп составның башка токымнары билгеләнә. Ю.К.и. чикләрендәге Татарстан терр-ясендә күп кенә файдалы казылмаларның: нефть, кирпеч балчыклары, ком-вакташ һ.б. чыганаклары билгеле.

*Әд.:* В а л е е в Р.Н. Авлакогены Восточно-Европейской платформы. М., 1976; Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоносности. К., 1996.

**ЮГАРЫ́ КАНДЫ́З** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 59,7 *км*, ТР чикләрендә 20 *км*. Бассейнының мәйданы 590,4 $км^2$. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Баулы р-нында ага. Елга башы Оренбург өлкәсе терр-ясендә, тамагы Шалты авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 270 *м*, тамагыныкы — 123 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 13%. Ю.К.ның 13 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Шалты (12,9 *км*) — уң; Куй елгасы (15,3 *км*), Күннә (11,1 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,26 $км/км^2$. Туенуы катнаш, 56% ка кадәре кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3,1–5 $л/с\cdot км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 144 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 1,3 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л* (югары агымында 700–1000 *мг/л*), кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Су ресурслары сугару һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла. Ю.К. бассейнында *Салих тавы* табигать истәлеге урнашкан.

**ЮГАРЫ́ КАРАКИТӘ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 20 *км* көнбатыштарак, Бизнә елгасы (Суранның уң кушылдыгы) бассейнында. 2010 елда 467 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 17 йөзгә кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашман хезмәтен үти; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1883 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.К.дә мәчет, йон-тукыма ману йорты эшли. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 166,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Мөчәли волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 1021, 1883 тә — 1255, 1911 дә — 2008, 1920 дә — 1887, 1926 да — 1826, 1938 дә — 1733,

1949 да — 1915, 1958 дә — 984, 1970 тә — 1138, 1979 да — 1151, 1989 да — 646, 2002 дә — 467 кеше.

**ЮГАРЫ́ КАРАМАЛЫ́** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 12 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Карамалы елгасы буенда. 2010 елда 212 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 70%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.К.да чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе эшли; 6–12 декабрьдә ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3227 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Югары Карамалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 350, 1897 дә — 1065, 1920 дә — 1235, 1926 да — 917, 1949 да — 639, 1958 дә — 505, 1970 тә — 450, 1989 да — 280, 2002 дә — 239 кеше.

**ЮГАРЫ́ КАРА́Н** посёлогы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 10 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 34 кеше (руслар) яши. 1927 дә нигез салына. Күмәкләштерү елларында Ю.К.да «Память Орджоникидзе» к-зы оештырыла, 1937 дә «Крестьянин» күмәк хуҗалыгына керә, 1957 дән — «Лениногорский» с-зында. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 114, 1938 дә — 110, 1949 да — 95, 1958 дә — 87, 1970 тә — 52, 1979 да — 28, 1989 да — 9, 2002 дә — 14 кеше.

**ЮГАРЫ́ КАРА́Ч** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 26 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше (татар) яши. 18 йөздә нигез салына. 18 — 19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмгатенең имана җире 276 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров (Өшәр) волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1816 да — 26 ир-ат; 1859 да — 63, 1870 тә — 70, 1897 дә — 127, 1913 тә — 154, 1920 дә — 145, 1926 да — 75, 1938 дә — 102, 1949 да — 65, 1958 дә — 56, 1970 тә — 60, 1979 да — 39, 2002 дә — 1 кеше.

**ЮГАРЫ́ КАРМАЧЫ́** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 18 *км* төньяктарак, Казан — Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 15 кеше (руслар) яши. Казан ханлыгы чорыннан билгеле, руслар 16 йөзнең 2 нче яртысында килеп урнаша. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 18 йөз уртасында Ю.К.ның бер өлеше шагыйрь Г.Р.Державинның әти-әнисе утарына керә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 84,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 150, 1897 дә — 254, 1908 дә — 296, 1920 дә — 273, 1926 да — 280, 1938 дә — 196, 1949 да — 138, 1958 дә — 162, 1970 тә — 92, 1979 да — 36, 1989 да — 18, 2002 дә — 13 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**ЮГАРЫ́ КӘМИНКӘ́** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 18 *км* төньяктарак, Олы Кәминкә елгасы буенда. 2010 елда 342 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.К.дә мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп, тегермән, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1664 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Кутәмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 29 ир-ат; 1859 да — 635, 1897 дә — 1344, 1908 дә — 1590, 1920 дә — 1520, 1926 да — 1610, 1949 да — 660, 1958 дә — 671, 1970 тә — 774, 1979 да — 641, 1989 да — 393, 2002 дә — 365 кеше.

**ЮГАРЫ́ КӘЧИ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 38 *км* көньяктарак, Шыя елгасы (Кече Чирмешән бассейны) буенда. 2010 елда 169 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.К.дә земство мәктәбе, 4 тегермән, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1330 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Успение-Юхмачы волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1859 да — 391, 1897 дә — 654, 1908 дә — 661, 1926 да — 436, 1938 дә — 390, 1949 да — 379, 1958 дә — 345, 1970 тә — 447, 1979 да — 367, 1989 да — 247, 2002 дә — 200 кеше.

**ЮГАРЫ́ КЕНӘ́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 13 *км* көнбатыштарак, Хәтнә елгасы буенда. 2010 елда 109 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мәскәү Чишмәсе, Алан-Елга буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.К.дә мәчет һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең (Түбән Кенә авылын да кертеп) имана җире 1940,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 79 ир-ат; 1859 да — 262, 1897 дә — 386, 1908 дә — 425, 1920 дә — 323, 1926 да — 301, 1949 да — 208, 1958 дә — 179, 1970 тә — 160, 1979 да — 118, 1989 да — 84, 2002 дә — 81 кеше.

**ЮГАРЫ́ КИБӘХУҖА́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 12 *км* төньяк-көнбатыштарак, Макса елгасы буенда. 2010 елда 420 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Йосыф исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.К.да мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, ярма яргыч, 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2285,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Олы Кибәхуҗа волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1859 да — 628, 1897 дә — 806, 1908 дә — 927, 1926 да — 946, 1938 дә — 943, 1949 да — 746, 1958 дә — 715, 1970 тә — 726, 1979 да — 577, 1989 да — 434, 2002 дә — 432 кеше.

**ЮГАРЫ́ КОЗГЫНЧЫ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мамадыш–Кукмара автомобиль юлы буенда. 2010 елда 115 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1710 нан билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.К.да мәчет, мәктәп, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 294,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 августыннан — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 216, 1897 дә — 334, 1908 дә — 372, 1926 да — 223, 1949 да — 174, 1958 дә — 184, 1970 тә — 199, 1979 да — 170, 1989 да — 146, 2002 дә — 126 кеше.

**ЮГАРЫ́ КОЛЧУРА́** (Биктебай) авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Инча елгасы (Кече Чирмешән бассейны) буенда. 2010 елда 219 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 71%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Ыштыбай исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт һәм удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.К.да Рождество чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1891 дә ачыла), 3 җил тегермәне, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2438,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Кузнечиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 146 ир-ат; 1859 да — 450, 1897 дә — 740, 1908 дә — 792, 1920 дә — 1226, 1926 да — 1057, 1938 дә — 572, 1949 да — 555, 1958 дә — 683, 1970 тә — 494, 1979 да — 359, 1989 да — 281, 2002 дә — 253 кеше.

**ЮГАРЫ́ КОНДРАТА́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 50 *км* көньяктарак, Баганалы елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 339 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 68%, чуашлар — 31%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 20 йөз башында Ю.К.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, 2 тегермән, ярма яргыч, тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1254 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Алексеев, 1987 нең апреленнән Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 87 ир-ат, 1859 да — 442, 1897 дә — 830, 1908 дә — 959, 1920 дә — 945, 1926 да — 522, 1938 дә — 556, 1949 да — 510, 1958 дә — 629, 1970 тә — 626, 1989 да — 425, 2002 дә — 380 кеше.

**ЮГАРЫ́ КӨЕ́К** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үртәм елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 261 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Көек, Иске Көек исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.К.тә волость идарәсе урнаша; мәчет, җил тегермәне, тимерче алачыгы, мануфактура һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1175 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Краснококшайск (1919 га кадәр — Царёвококшайск) өязе Күлле Киме волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 2 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 35 ир-ат; 1859 да — 580, 1897 дә — 783, 1908 дә — 966, 1920 дә — 994, 1926 да — 1005, 1938 дә — 1022, 1949 да — 764, 1958 дә — 620, 1970 тә — 622, 1979 да — 617, 1989 да — 367, 2002 дә — 286 кеше.

**ЮГАРЫ́ КУМО́Р** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 12 *км* көнбатыштарак, Оштырма елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 335 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — ит терлеге асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 16 йөз ахырында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек басу, йон тетү б-н шөгыльләнә. 1875 тә Ю.К.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе ачыла, 1912 дә земство мәктәбе итеп үзгәртелә. 20 йөз башында Ю.К.да ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1022,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 71 ир-ат; 1859 да — 446, 1897 дә — 574, 1908 дә — 595, 1920 дә — 560, 1926 да — 488, 1938 дә — 475, 1949 да — 422, 1958 дә — 420, 1970 тә — 431, 1979 да — 460, 1989 да — 308, 2002 дә — 341 кеше.

**ЮГАРЫ́ КУРСА́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 8 *км* көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы буенда. 2010 елда 202 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мич чыгару, балта эше, тегү, тире иләү, йон тетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.К.да мәчет (19 йөз уртасында төзелә; архит-ра истәлеге), мәдрәсә (19 йөздә Казан артында танылган дини уку йортларының берсе), 2 су тегермәне, тимерче алачыгы, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Түбән Курса авылын да кертеп) 4398 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 175 ир-ат; 1859 да — 923, 1897 дә — 1197, 1908 дә — 1360, 1920 дә — 1484, 1926 да — 1412, 1958 дә — 397, 1970 тә — 313, 1979 да — 273, 1989 да — 211, 2002 дә — 207 кеше.

**ЮГАРЫ́ КҮЗМИ́С** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 26 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 313 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1930 елларга кадәр Казан ханлыгы чорыннан билгеле Күзмис авылына Ю.К. һәм Түбән Күзмис авыллары керә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында җирле халык дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Күзмис авылында Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1908 дә ачыла), су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1269,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1922 дән — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 262, 1897 дә — 431, 1908 дә — 414, 1920 дә — 568, 1926 да — 544, 1938 дә — 490, 1949 да — 422, 1958 дә — 419, 1970 тә — 513, 1979 да — 386, 1989 да — 328, 2002 дә — 342 кеше.

**ЮГАРЫ́ КҮЛ**, Идел алдында, элекке елга юлында сакланып калган күл. Зөя елгасының уңъяк яры тугаенда, Югары Ослан р-ны Карамышиха авылында урнашкан. Су өслегенең мәйданы 5,12 *га*. Озынлыгы 940 *м*, иң зур киңлеге 70 *м*.

**ЮГАРЫ́ КЫЯРЛЫ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 46 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасы буенда. 2010 елда 339 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Май з-ды. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1627 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кырлы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.К.да мәчет, мәктәп, су тегермәне, пар б-н эшләүче такта яру з-ды, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1341,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сон волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 98 ир-ат; 1859 да — 615, 1897 дә — 1008, 1908 дә — 1170, 1920 дә — 1203, 1926 да — 1137, 1949 да — 760, 1958 дә — 944, 1970 тә — 866, 1979 да — 741, 1989 да — 506, 2002 дә — 407 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЛАШЧЫ́** (Лашчы Башы) авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Лашчы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 234 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашман хезмәтен үти; игенчелек,

терлекчелек, икмәк сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Л.да мәчет һәм мәдрәсә эшли. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Янтуган волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 253, 1897 дә — 598, 1911 дә — 1094, 1920 дә — 1025, 1926 да — 943, 1938 дә — 808, 1949 да — 641, 1958 дә — 533, 1970 тә — 465, 1979 да — 414, 1989 да — 256, 2002 дә — 249 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЛОЖЫ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 32 *км* төньяктарак, Ложы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 142 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, вак һөнәрчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.Л.да мәчет, мәдрәсә, су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 643 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү чорында «Кызыл Тау» к-зы оештырыла. 1950 дә ул «Илшат» берләштерелгән күмәк хуҗалыгы, 1959 да «Алга» к-зы (1998 дән — а.х. товарлары җитештерү кооперативы) составына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 241, 1897 дә — 525, 1920 дә — 776, 1926 да — 630, 1938 дә — 578, 1949 да — 530, 1970 тә — 504, 1979 да — 405, 1989 да — 267, 2002 дә — 174 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ЮГАРЫ́ МАКТАМА́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 12 *км* көньяктарак, Мактама елгасы буенда. 2010 елда 1061 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, кошчылык. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында Казан өязе Алат даругасының Бәрәскә һәм Үртәм авылларыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мактамабаш исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, таш вату, тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.М.да мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп, 5 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3714 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 151 ир-ат; 1795 тә — 415, 1859 да — 940, 1897 дә — 1316, 1920 дә — 1535, 1926 да — 1250, 1938 дә — 1281, 1949 да — 1116, 1958 дә — 1098, 1970 тә — 1111, 1979 да — 966, 1989 да — 750, 2002 дә — 934 кеше.

**ЮГАРЫ́ МАСРА́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кесмәс елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 85 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.М.да мәчет, мәктәп, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1006,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 105 ир-ат; 1859 да — 491, 1897 дә — 532, 1908 дә — 598, 1920 дә — 667, 1926 да — 522, 1938 дә — 545, 1958 дә — 358, 1970 тә — 260, 1979 да — 222, 1989 да — 153, 2002 дә — 111 кеше.

**ЮГАРЫ́ МАТА́К** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 10 *км* көньяк-көнбатыштарак, Актай елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 240 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1710 нан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чуаш Төгәлбае исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.М.та Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, 2 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1120,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 93 ир-ат; 1859 да — 355, 1897 дә — 590, 1908 дә — 674, 1926 да — 544, 1938 дә — 511, 1949 да — 456, 1958 дә — 473, 1970 тә — 554, 1989 да — 293, 2002 дә — 258 кеше.

**ЮГАРЫ́ МӘЛЕ́М** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 36 *км* көнчыгыштарак, Мәлем елгасы буенда. 2010 елда 339 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр сугышында Пугачёв отрядының Зәй кальгасен камаганчы (1773 нең дек. — 1774 нең гыйн. башы) туплану урыны була. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чыпта-кап сугу, мичкә ясау, олаучылык б-н шөгыльләнә; алпавыт утарларында ялланып эшли. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.М.дә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 1558 дис. тәшкил итә. 1924 тә Ю.М.нең берничә крәстиян хуҗалыгы Яңа Мәлем авылына нигез сала. 1926–27 дә җирне бергәләп эшкәртү ширкәте оештырыла, күмәкләштерү чорында аның җирлегендә «Кызыл Октябрь» к-зы төзелә. 1954 тә — берләшкән «Кызыл Таң» хуҗалыгы, 1959 дан Ленин исем. колхоз (1997 дән — «Мәлем» а.х. товарлары җитештерүче кооператив) составында. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 458, 1870 тә — 591, 1897 дә — 1024, 1913 тә — 1231, 1920 дә — 1319, 1926 да — 594, 1938 дә — 581, 1949 да — 607, 1958 дә — 517, 1970 тә — 447, 1979 да — 382, 1989 да — 317, 2002 дә — 345 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ЮГАРЫ́ МӘТӘСКӘ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ия елгасы буенда. 2010 елда 280 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү, юкәдән иләк ясау б-н шөгыльләнә, почта атлары тота. 20 йөз башында Ю.М.дә мәчет һәм мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 817,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 90 ир-ат; 1859 да — 366, 1897 дә — 405, 1908 дә — 452, 1920 дә — 460, 1926 да — 480, 1938 дә — 507, 1949 да — 332, 1958 дә — 300, 1970 тә — 312, 1979 да — 278, 1989 да — 270, 2002 дә — 285 кеше.

**ЮГАРЫ́ МӘТӘСКӘ́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 12 *км* көнбатыштарак, Мәтәскә елгасы буенда. 2010 елда 196 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.М.дә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 860 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 136 ир-ат; 1859 да — 525, 1897 дә — 780, 1908 дә — 953, 1920 дә — 831, 1926 да — 700, 1938 дә — 686, 1949 да — 552, 1958 дә — 440, 1970 тә — 422, 1979 да — 336, 1989 да — 245, 2002 дә — 222 кеше. Ю.М.дә язучы Ф.*Хөсни* туган.

**ЮГАРЫ́ МӘШЛӘ́К** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 50 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 162 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1710 га кадәр Янсуар авылын-

нан күченүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү, күмер сату б-н шөгыльләнә. 1861 елгы реформадан соң Ю.М.тә руслар урнаша. 20 йөз башында Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1888 дә ачыла, 1908 дә земство мәктәбе итеп үзгәртелә), су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 713,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе.р-нында. Халык саны: 1782 дә — 80 ир-ат; 1859 да — 294, 1897 дә — 447, 1908 дә — 558, 1920 дә — 509, 1926 да — 423, 1938 дә — 370, 1949 да — 285, 1958 дә — 237, 1970 тә — 200, 1989 да — 103, 2002 дә — 178 кеше.

**ЮГАРЫ́ МИРӘТӘ́К** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 23 *км* көньяктарак, Нырсы елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 25 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөзнең 2 нче яртысында Олы Мирәтәк авылыннан күченүчеләр нигез сала. Беренче исеме — Яңа Мирәтәк. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.М.тә чиркәү-приход мәктәбе, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 517,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Казиле волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1859 да — 229, 1897 дә — 559, 1908 дә — 588, 1920 дә — 548, 1926 да — 459, 1938 дә — 332, 1949 да — 326, 1958 дә — 218, 1970 тә — 140, 1979 да — 91, 1989 да — 46, 2002 дә — 35 кеше.

**ЮГАРЫ́ МОЛЕКУЛЯ́Р КУШЫЛМАЛА́Р**, атомнары ковалент һәм (яки) донор-акцептор (координацион) бәйләнешләр ярдәмендә үзара кушылып макромолекулалар хасил иткән югары молекуляр массалы (берничә меңнән алып берничә миллионга кадәр) химик кушылмалар. Килеп чыгышлары буенча табигый (аксымнар, нуклеин кислоталары, целлюлоза, табигый каучук, комташ, кварц, силикатлар һ.б.) һәм ясалма (полиэтилен, поливинилхлорид, поливинил спирты, синтетик *каучук* һ.б.) кушылмаларга бүленә. Органик характерлы табигый Ю.м.к. тере организмнар күзәнәкләрендә биосинтез процессы нәтиҗәсендә, нәорганик Ю.м.к. (углеродсызлар) җир кабыгында узучы геохимик процесслар нәтиҗәсендә барлыкка килә. Синтетик Ю.м.к.ны түбән молекуляр кушылмалар — мономерлардан полимерлаштыру яки поликонденсацияләү, ш.у. табигый Ю.м.к.ны химик үзгәртү юлы б-н барлыкка китерәләр. Бер үк төзелешле кабатланучы буыннардан торган молекуляр чылбырга ия нәлинияле һәм аз тармаклы Ю.м.к. полимер дип атала. Ю.м.к.ның төп сыйфатламалары — химик состав, молекуляр масса, молекуляр масса таралышы, буыннар торышы стереорегулярлыгы, тармаклану һәм берегү дәрәҗәсе. Конденсацияләнгән халәттәге макромолекулаларны урнаштыру (туплау) ысулы аларның төзелешенә бәйле. Регуляр макромолекулалардан кристаллар, нәрегулярлардан аморф системалар хасил була. Пластик массалар, резиналар, җепселләр, элпәләр, каклар, эмальләр, җилемнәр һ.б. сыйфатындагы Ю.м.к. күп кенә халык хуҗалыгы тармакларында, медицинада, космик һәм оборона техникасында кулланыла. Ю.м.к. тере организмнарның нигезен тәшкил итә, тереклек эшчәнлеге процессларында катнаша.

Ю.м.к.ның чылбыр төзелеше һәм синтезы теориясенең төп нигезләмәләре 1930–50 елларда формалаштырыла. Ю.м.к.ны тикшерүгә Г.Штаудингер, У.Кароserved, П.Флори, В.А.Каргин, В.В.Коршак һ.б. зур өлеш кертә. 1950–60 елларда Татарстанда Б.А.Арбузов, Г.Х.Камай, А.Н.Пудовик, П.А.*Кирпичников*, Е.В.*Кузнецов*, В.А.*Воскресенский* Ю.м.к.да полимерлашу процесслары, стабильләшү һәм пластиклашуның теоретик һәм гамәли аспектлары, ш.у. полимер композицион материалларны барлыкка китерү буенча фәнни юнәлешләргә җитәкчелек итәләр. 1960 елларда нәорганик Ю.м.к. — төп чылбырында Si-O, P-O, B-O бәйләнешләре булган полиэлементоксаннар химиясе һәм технологиясе буенча фәнни юнәлеш булдырыла (Е.В.Кузнецов, Л.И.Кузнецов-Фетисов, В.В.Герасимов, О.С.Сироткин). Бу Ю.м.к. органик һәм элементорганик Ю.м.к.дан эссегә һәм атмосферага карата югары дәрәҗәдә чыдам булулары б-н аерылып тора. Шул ук елларда башка уңышларга да ирешелә: полимер электролит эремәләре өлкәсендә систематик тикшеренүләр башлана (С.М.Кочергин, В.П.Барабанов); олефиннарны (В.И.Гусев), акрил һ.б. чиксез кислоталарны һәм аларның чыгарылмаларын, акриламидны (В.А.Мягченков, В.Ф.Куренков) һ.б. полимерлаштыру башкарыла. Яңа мономерлар (ш.и. элементорганик мономерлар), функциональ кулланышлы полимерлар: эчендә фосфор һәм кремний булган элементорганиклар (Б.Е.Иванов, И.М.Шермергорн, Я.А.Левин, Е.П.Лебедев), күкертле элементорганиклар (полисульфид каучуклар) (Л.А.Аверко-Антонович, В.С.Минкин, Е.С.Нефедьев), полиуретаннар һәм полиизоцианатлар (М.Һ.Бахитов, В.П.Архиреев, Ю.О.Аверко-Антонович, Л.А.Зенитова), оптика өлкәсендә кулланылучы полимерлар, ш.и. фотохром материаллар, буягычларда полимер лазерлы тирәлекләр, антистатик һәм парланмаучан капламалар (Л.Х.Хәзрәтова, В.Н.Серова), суда эрүчән полимерлар — табигый һәм ясалма дисперсияләр флокулянтлары (В.А.Мягченков, В.Ф.Куренков) синтезлана. Полимерларны электр ярдәмендә утырту өчен алдан бирелгән үзенчәлекле югары сыйфатлы капламалар барлыкка китерү мөмкинлеге тудырыла (В.П.Барабанов, Г.Я.Вяселева). Өч координатлы фосфор атомлы кушылмаларны, алкиландырылган фенол чыгармалары, бис-феноллар һәм Манних нигезләрен кулланып Ю.м.к.ны стабильләштерү өйрәнелә (П.А.Кирпичников, Д.Г.Победимский, Н.А.Мукменева). Ю.м.к.да пластиклашу (В.А.Воскресенский, В.Г.Хуҗин), химик актив кушылмаларны аз-азлап өстәп полимерларны легирлау (В.П.Архиреев, Р.Я.Дибердиев, Е.М.Готлиб, О.В.Стоянов, А.М.Кочнев) буенча эш циклы башкарыла. Органик һәм нәорганик чыгышлы полимерларны чыганактан чыгарылган нефть күләмен арттыру өчен тампонаж продуктлары буларак куллану тикшерелә һәм нефть сәнәгатендә кулланыла (Е.В.Кузнецов, В.П.Барабанов, С.В.Крупин). Полимерларның тулыландырылган гетероген катнашмалары нигезендә композицион материаллар, ш.и. электр үткәрүчән полимер материаллар, конструкцияләү өлкәсендә кулланылучы материаллар, динамик термоэластик пластлар (С.И.Вольфсон, А.Е.Заикин), җепселләр һ.б. барлыкка китерелә. Ю.м.к. өлкәсендәге тикшеренүләр б-н РФА КГҮнең органик һәм физик химия ин-ты, Казан технол. ун-ты, Казан ун-ты, Казан архитектура-төзелеш академиясе, Полимерлар һәм махсус каучуклар ин-ты, «Түбәнкаманефтехим»АҖнең фәнни тикшеренүләр һәм тәҗрибә эшләре идарәсе лаб-яләре һ.б. шөгыльләнә. Күп кенә гамәли нәтиҗәләр сәнәгатькә кертелә («Түбәнкаманефтехим» АҖ, «Органик синтез» АҖ, «С.М.Киров исем. синтетик каучук з-ды» фәнни-тикшеренү берләшмәсе һ.б.).

*Әд.:* Каргин В.А., Слонимский Г.А. Краткие очерки по физико-химии полимеров. М., 1967; Энциклопедия полимеров. М., 1972. Т. 2; Оудиан Дж. Основы химии полимеров. М., 1974; Элиас Г. Мегамолекулы. Л., 1990.

*В.П.Архиреев.*

**ЮГАРЫ́ МӨСЕЛМА́Н КОЛЛЕ́ГИЯСЕ**, 1938–39 елларда Вильно (Вильнюс) шәһәрендә Польша-Литва татарлары мөфтиятенең башкарма органы. Бөтенполяк мөселман конгрессында оештырыла. Составы: А.Воронович, А.Крыницкий, О.Крычыньский, Я.Романович, Я.Мишкевич, Л.Мухля, К.Мурза-Мурзич һәм С.-М.Романович. Коллегия дини гминалар әгъзаларының гомуми җыелышларын уздыра, стат. мәгълүматлар җыю, мәчетләр төзү, зиратларны тәзекләндерү һ.б. б-н шөгыльләнә.

*Я.Я.Гришин.*

**ЮГАРЫ́ НАРАТБА́Ш** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 7 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 123 кеше (татарлар) яши. Мәчет. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1840 еллар башына кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, олаучылык, чабата үрү һәм сату б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.Н.та мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 894,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырынгы волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык са-

ны: 1859 да — 608, 1897 дә — 930, 1913 тә — 1334, 1920 дә — 1066, 1926 да — 630, 1938 дә — 517, 1958 дә — 430, 1970 тә — 479, 1979 да — 404, 1989 да — 190, 2002 дә — 152 кеше.

**ЮГАРЫ́ НУРЛА́Т** авылы, Нурлат шәһәре составында, Нурлат шәһәреннән 5 *км* көнчыгыштарак, Кондырча елгасы буенда. 2000 елда 709 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — ит терлеге асрау, чөгендер үстерү. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Авыл тарихы музее. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Н.та мәчет (1905 тә төзелә), мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3045 дис. тәшкил итә. 1928 гә кадәр Самара губернасының Мәләкәс өязе Шламка волостенда, 1928 нең 23 гыйнварыннан ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында, 2001 нең 27 июненнән Нурлат шәһәре карамагында. Халык саны: 1897 дә — 987, 1926 да — 1147, 1938 дә — 951, 1949 да — 721, 1958 дә — 772, 1979 да — 852, 1989 да — 668 кеше.

**ЮГАРЫ́ ОРЫ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 45 *км* төньяктарак, Оры елгасы буенда. 2010 елда 213 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1646 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Оры иселе б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.О.да мәчет, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1540,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск өязе Шиңшә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 663, 1897 дә — 869, 1908 дә — 942, 1926 да — 949, 1938 дә — 818, 1949 да — 568, 1958 дә — 474, 1970 тә — 365, 1979 да — 274, 1989 да — 225, 2002 дә — 217 кеше.

**ЮГАРЫ́ ОСЛА́Н** авылы, Югары Ослан р-ны үзәге. ТРның көнбатыш өлешендә, Казан тимер юл станциясеннән 11 *км* көнбатыштарак, Идел елгасының уң ярында урнашкан. 2010 елда 4499 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 65%, татарлар — 27%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Хуҗалыкара төзелеш оешмасы, «Агропромдорстрой» АҖ, «Агрохимсервис» пр-тиесе, «Югары Ослан» консерв һәм икмәк з-длары, басмаханә. Урта мәктәп, гимназия, музыка мәктәбе, район мәдәният йорты, 2 китапханә. 1575 елларда Зөя Троица Сергий монастыре терр-ясендә нигез салына. 1764 тә җирле халык монастырь крәстияннәреннән — економик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек, яшелчәчелек, бакчачылык, мичкә ясау, Идел аша пассажирлар ташу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.О.да волость идарәсе, йөк күчерү пристане урнаша; Никола чиркәве (1831—38 дә төзелә; архит-ра истәлеге), почта-телеграф бүлекчәсе, шәхси даруханә, чиркәү-приход мәктәбе (1888 дә ачыла), Халык мәгарифе министрлыгы уч-ще-се, казна арба ясау остаханәсе, җил тегермәне, 2 тимерче алачыгы, 4 сыраханә, 2 чәйханә, казна шәраб һәм 16 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1645 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Югары Ослан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Зөя р-нында, 1931 нең 20 октябреннән Югары Ослан р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән Зеленодольск р-нында, 1965 нең 12 гыйнварыннан кабат Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 374 ир-ат; 1859 да — 1358, 1897 дә — 1634, 1908 дә — 1849, 1926 да — 2113, 1949 да — 2617, 1958 дә — 2743, 1970 тә — 2759, 1979 да — 2817, 1989 да — 3788, 2002 дә — 4257 кеше.

*Әд.:* Приволжские города и селения в Казанской губернии. К., 1892; Верхний Услон: край родной, навек любимый... К., 2001.

**ЮГАРЫ́ ОСЛА́Н РАЙОНЫ́**, ТРның көнбатыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 1373 *км*². 1 шәһәр, 19 авыл җирлеген, 74 торак пунктны берләштерә. Үзәге — *Югары Ослан* авылы. Халкы — 16457 кеше (2017). 2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 67,1%, татарлар — 23,7%, чуашлар — 6,8%. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 12,8 кеше. Район 1931 нең 20 октябрендә оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Зөя өязенә, 1920–27 елларда ТАССРның Зөя кантонына, 1927–31 дә Зөя һәм Тәмте р-нnарына керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 950 *км*², халкы — 41,5 мең кеше, 28 авыл советы, 90 торак пункт була. 1958 нең 16 июлендә Ю.О.р.на таркатылган *Тәмте районының* бер өлеше кушыла. 1960 та районның мәйданы 1315,9 *км*² җир били, аңа 15 авыл советы, 107 торак пункт керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, Ю.О.р. бетерелә (1963 нең 1 февр.), терр-ясе Зеленодольск р-нына бирелә. Район кабат торгызылгач (1965 нең 12 гыйнвары), мәйданы — 1322 *км*², халкы 33,5 мең кеше була, 15 авыл советы, 97 торак пункт исәпләнә.




Ю.О.р. рельефы калкулыклы (биеклеге 53–224 *м*), инеш-елга үзәннәре һәм чокырлар б-н нык бүлгәләнгән. Куйбышев сусаклагычы. Районның төньяк һәм көнчыгыш чикләрен — Идел, көнбатыш чикләрен Зөя елгасы юа, кушылдыклары б-н Сөлчә елгасы ага. Җирләре күбесенчә аксыл соры һәм соры урман, кәсле-карбонатлы туфраклы. Терр-ясенең 16,3% ы — урманлык. Доломит, известьташ, кәрәчле туф, балчык һәм мергель ятмалары бар. Саклаулы табигать объектлары: Зөя һәм Сөлчә елгалары, *Кул*, *«Зөя»* комплекслы табигать тыюлыгы; табигать истәлекләре: *«Казан университеты зоостанциясе» — «Дачный» урман массивы*, *Тау нараптыгы*, *Кликовка сөзәклеге*; геол. табигать истәлекләре: *Ташлы ерым* һәм *Черёмушки* ерымы, *Печище геологик киселеше*, *Тәмте аучылык тыюлыгы*. Район терр-ясендә бронза гасырдан алып болгар чорына кадәрге 100 ләп археол. истәлек табыла. Ю.О.р.нда а.х. тармагы







Югары Ослан авылы. 1. Авылның үзәге; 2. Никольский чиркәве. 1831–38; 3. «Теремок» ятим балалар һәм яшүсмерләр йорты.

алга киткән. А.х. җирләре — 70,7 мең *га*, сөрүлекләр — 47,4 мең *га* (2018). Бөртекле ашлык, терлек азыгы, җиләк-җимеш культуралары, бәрәңге, рапс, кукуруз үстерелә. Идел елгасы ярында бакчалар урнашкан. Мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау алга киткән. 2016 елда районда 5 а.х. пр-тиесе эшли. «Иннополис» техника-гамәлгә кертү тибындагы аерым икътисади зонасы, «Матюшинский карьер» (Матюшино а.), «Керамика-синтез» һәм «Клюкер» кирпеч (Шылаңгы, Ключище а.), «Дивный берег»консерв (Яр буе Морквашы а.), крахмал-патока (Куралово а.) з-длары; икмәк комб-ты (Печище а.), «Вельветте Марин» суднолар төзү компаниясе һәм «Геоник» коммерция-житештерү фирмасы (нефть чыгару җиһазлары җитештерә) (Яр буе Морквашы а.). Урман хуҗалыгы. Казан–Ульянов, Югары Ослан–Кама Тамагы автомобиль юллары уза, Идел аша автомобиль күпере, Югары Осланда, Шылаңгыда һ.б. торак пунктларда пристань эшли. «Газовик» дәвалау-сәламәтләндерү профилакторие (Пустые Моркваши), *«Казан» тау спорты сәламәтләндерү комплексы* (Савино а.), гольф-клуб, «Свияга» стендта ату комплексы (Медведково а.) урнашкан. Ю.О.р.нда 20 гомуми белем бирү һәм балалар сәнгать мәктәбе, лицей, 2 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, 19 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 33 клуб, 27 китапханә, 1 хастаханә, 2 дәвалау амбулаториясе, 30 фельдшер-акушерлык пункты бар. Печище авылында Янка Купала һәм Югары Осланда төбәк тарихы музее эшли. Рус телендә «Волжская новь» район г-тасы нәшер ителә.

*Әд.:* Верхний Услон: край родной, навек любимый... К., 2001.

**ЮГАРЫ́ ОСЛА́Н ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, муниципаль музей, 2001 елның 20 октябрендә ачыла. Ике катлы кирпеч бинаның 2 нче катын һәм 1 нче катының бер өлешен алып тора. Экспозиция мәйданы — 206,8 $м^2$, фондларында 1086 саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция ике залда урнашкан. «Борынгы заманнардан алып 1917 елга кадәр төбәк тарихы» бүлегендә экспозициягә археол. коллекция, дворяннар һәм сәүдәгәрләрнең көнкүреш әйберләре, төбәкнең 19–20 йөзләр тарихына караган фоторәсемнәр һәм документлар, район терр-ясендә яшәгән халыкларның (татарлар, руслар, чуашлар) костюмнары куелган. Күргәзмәдә «Ям станциясе» («Ямская станция»), «Дача чатыры» («Дачная беседка»), «20 йөз башында крәстиян ызбасы» («Крестьянская изба 20 в.») интерьер фрагментлары урын алган. Экспозициянең икенче бүлеге төбәкнең 1917 елдан алып безнең көннәргә кадәр тарихын ачып бирә: Гражданнар сугышы вакытындагы корал фрагментлары, төбәктә туып-үскән кешеләрнең, ш.и. Сов. Союзы Геройлары А.П.*Афанасьев*, А.А.*Гаврилов*, Н.Ш.*Зиннуров*, А.П.*Исаев*, М.В.*Красавин*, С.В.*Коновалов* документлары һәм фоторәсемнәре урнаштырылган. 1950–60 еллар мәктәбенең сыйныф бүлмәсе интерьеры торгызылган. Музей ел саен А.С.Пушкинны искә алу көнен (10 февр.), Г.Тукайга багышланган шигырь бәйрәмен (26 апр.), Җиңү көнен (9 май) билгеләп уза.





Югары Ослан төбәк тарихы музее. 1. Гомуми күренеше; 2. Экспозиция фрагменты.

**ЮГАРЫ́ ОШТЫРМА́** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оштырма елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 2 кеше (татарлар) яши. 1710 нан мәгълүм. Беренче булып удмуртлар килеп урнаша, соңрак аларны татарлар кысрыклап чыгара. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.О.да мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 254,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 13 ир-ат; 1859 да — 119, 1897 дә — 150, 1908 дә — 182, 1920 дә — 190, 1926 да — 212, 1938 дә — 213, 1949 да — 219, 1958 дә — 152, 1970 тә — 75, 1979 да — 21, 1989 да — 5, 2002 дә — 4 кеше.

**ЮГАРЫ́ ӨСКЕБА́Ш** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 21 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Өске елгасы буенда. 2010 елда 218 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә.17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Ө.та мәчет, мәктәп, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 959,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш-Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 39 ир-ат; 1859 да — 477, 1897 дә — 753, 1908 дә — 860, 1920 дә — 892, 1926 да — 1206, 1949 да — 663, 1958 дә — 533, 1970 тә — 404, 1979 да — 352, 1989 да — 280, 2002 дә — 244 кеше.

**ЮГАРЫ́ ПӘНӘЧЕ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 30 *км* төньяктарак, Аулаш елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 280 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Черемисская Пустошь, Тимер-Тамак исемнәре б-н дә билгеле. 1773—75 тәге Крәстияннәр кузгалышында халкы Пугачёв отряды ягында сугыша. 1860 елларга кадәр алар дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, чыпта сугу, Чаллы почта юлында олаучылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.П.дә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне эшли. Янган агач мәчет урынына 1890 да таш мәчет төзелә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 661 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү чорында (1929—30 еллар) авылда «Герой» к-зы оештырыла, 1959 да — «Якты Йолдыз» к-зы, 1983 тә «Ярыш» коллектив хуҗалыгы (1998 дән — а.х. товарлары җитештерү кооперативы) составына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1724 тә — 21, 1795 тә — 33 ир-ат; 1859 да — 273, 1897 дә — 501, 1920 дә — 741, 1926 да — 676, 1938 дә — 582, 1949 да — 539, 1958 дә — 303, 1970 тә — 461, 1979 да — 334, 1989 да — 233, 2002 дә — 301 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ЮГАРЫ́ ПОШАЛЫ́М** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 19 *км* төньяктарак, Пошалым елгасы буенда. 2010 елда 359 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1619 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Нырты, Пошалымбаш исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, агач әйберләр — чана, арба, чиләк һ.б. ясау б-н шөгыльләнә. Авыл аша узган Себер почта юлы авыл тормышында әһәмиятле роль уйный. Ю.П. халкы 19 йөзнең 40 елларында *«Бәрәңге фетнәләре»*ндә актив катнаша. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1168,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча

кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 58 ир-ат; 1859 да — 505, 1897 дә — 843, 1908 дә — 963, 1920 дә — 1021, 1926 да — 948, 1938 дә — 773, 1949 да — 914, 1958 дә — 673, 1970 тә — 650, 1979 да — 542, 1989 да — 414, 2002 дә — 342 кеше. *Гобәйдуллиннар* нәселе Ю.П. авылы б-н бәйле.

**ЮГАРЫ́ СА́НИН ЧИШМӘСЕ́** посёлогы, Бөгелмә р-нында, к. *Вязовка*.

**ЮГАРЫ́ СӘКИНӘ́С** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 23 *км* көньяктарак, Пакшин елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 43 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 1710 нан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элеккеге Кама тимер з-дына беркетелгәннәр) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.С.тә Троица чиркәве (1895 тә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1886 да ачыла), 2 җил тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2044 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Троица-Сәкинәс волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 140 ир-ат; 1859 да — 775, 1897 дә — 1097, 1908 дә — 1395, 1920 дә — 1396, 1926 да — 1443, 1938 дә — 1146, 1949 да — 624, 1958 дә — 368, 1970 тә — 329, 1979 да — 208, 1989 да — 129, 2002 дә — 64 кеше.

**ЮГАРЫ́ СӘРДӘ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кызылсу елгасы буенда. 2010 елда 180 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Олы Сәрдә исеме б-н телгә алына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тимерчелек һәм он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.С.дә мәчет, 5 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 2 ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1925,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 288 ир-ат; 1859 да — 965, 1897 дә — 1194, 1908 дә — 1307, 1920 дә — 1281, 1926 да — 1368, 1938 дә — 1281, 1958 дә — 470, 1970 тә — 379, 1979 да — 309, 1989 да — 237, 2002 дә — 202 кеше.

**ЮГАРЫ́ СӘРДЕ́К** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 41 *км* төньяктарак, Киров өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 24 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 1920 елларда нигез салына. Беренче исеме — Яңа Сәрдек. Башта ТАССРның Арча кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1926 да — 56, 1938 дә — 305, 1949 да — 208, 1958 һәм 1970 тә — 195 әр, 1979 да — 127, 1989 да — 60, 2002 дә — 33 кеше.

**ЮГАРЫ́ СИМЕ́Т** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 18 *км* көнбатыштарак, Кече Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 434 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.С.тә мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1219,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 114 ир-ат; 1859 да — 403, 1897 дә — 896, 1908 дә — 1046, 1920 дә — 1282, 1926 да — 950, 1938 дә — 834, 1949 да — 777, 1970 тә — 681, 1979 да — 688, 1989 да — 462, 2002 дә — 415 кеше.

**ЮГАРЫ́ СОН** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 44 *км* көнбатыштарак, Сон елгасы буенда. 2010 елда 520 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1619 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, агач хәзерләү, курыс төшерү-мунчала һәм мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.С.да мәчет (хәзергәчә сакланган бинасы 1907 дә төзелә; архит-ра истәлеге), 2 су тегермәне, тимерче алачыгы, йон-тукымаману йорты, 6 вак-төякләр кибете була; дүшәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1996 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кече Кирмән волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 193 ир-ат; 1859 да — 947, 1897 дә — 1439, 1920 дә — 1670, 1926 да — 2106, 1938 дә — 1555, 1949 да — 999, 1958 дә — 1069, 1970 тә — 1019, 1979 да — 922, 1989 да — 701, 2002 дә — 663 кеше.

**ЮГАРЫ́ СУБА́Ш** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 25 *км* төньяктарак, Көшкәт елгасы буенда. 2010 елда 414 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмгатенең имана җире 588,5 дис. тәшкил итә. 1889 дан Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе эшли, 1911 дә земство мәктәбе итеп үзгәртелә. 1929 дан Ю.С. «Марс» (1976 дан — Тукай исем.) к-зы составында. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1876 да — 129, 1886 да — 225, 1926 да — 563, 1938 дә — 698, 1958 дә — 288, 1970 тә — 283, 1979 да — 306, 1989 да — 317, 2002 дә — 403 кеше.

**ЮГАРЫ́ СУЫКСУ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 13 *км* көньяктарак, Мәләкәс елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 292 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1678 дән Илтимер исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.С.да мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 1913 тә ир балалар һәм 2 кыз балалар мәктәбе эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1795 тә — 88 ир-ат; 1870 тә — 448, 1897 дә — 640, 1913 тә — 871, 1920 дә — 887, 1926 да — 622, 1938 дә — 692, 1949 да — 526, 1958 дә — 425, 1970 тә — 478, 1979 да — 323, 1989 да — 215, 2002 дә — 265 кеше.

**ЮГАРЫ́ ТАБЫ́Н** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Табын елгасы буенда. 2010 елда 417 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 17–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.Т.да мәчет, 1913 тә 2 мәчет һәм мәктәп эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 501, 1897 дә — 827, 1920 дә — 1109, 1926 да — 845, 1938 дә — 899, 1949 да — 671, 1958 дә — 546, 1970 тә — 526, 1979 да — 458, 1989 да — 399, 2002 дә — 395 кеше.

**ЮГАРЫ́ ТАРХА́Н** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 39 *км* көньяк-көнбатыштарак, Тархан елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 251 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәдәният

йорты. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, читкә китеп эшләү: утын ташу һәм кисү, балта эше, а.х.эшләре б-н шөгыльләнә. 1883 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.Т.да чиркәү-приход мәктәбе эшли. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Олы Тархан волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 383, 1883 тә — 594, 1910 да — 611, 1920 дә — 716, 1926 да — 741, 1938 дә — 772, 1949 да — 658, 1958 дә — 634, 1970 тә — 595, 1979 да — 433, 1989 да — 306, 2002 дә — 289 кеше.

**ЮГАРЫ́ ТАТА́Р МАЙНАСЫ́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 50 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Вәлүл елгасы буенда. 2010 елда 258 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Служилая Верхняя Майна исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Т.М.нда мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1186 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Биләр волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 168 ир-ат; 1859 да — 433, 1897 дә — 743, 1908 дә — 884, 1920 дә — 803, 1926 да — 561, 1938 дә — 597, 1949 да — 474, 1958 дә — 440, 1970 тә — 534, 1979 да — 406, 1989 да — 233, 2002 дә — 276 кеше.

**ЮГАРЫ́ ТӘКӘНЕ́Ш** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 47 *км* төньяк-көнбатыштарак, Оча елгасы буенда. 2010 елда 284 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Ошлан исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чана ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Т.тә мәчет, мәктәп, су тегермәне, йон-тукымаману йорты, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 835,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 374, 1897 дә — 717, 1908 дә — 785, 1920 дә — 550, 1926 да — 599, 1949 да — 392, 1958 дә — 327, 1970 тә — 376, 1979 да — 353, 1989 да — 260, 2002 дә — 282 кеше.

**ЮГАРЫ́ ТӘКЕРМӘ́Н** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 30 *км* көнбатыштарак, Казан — Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 524 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1709 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Тәкермән, Самин, Тасумень исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр, дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, арба, чана ясау, чабата сату б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында халкы Пугачёв отряды ягында сугыша. 1917 гә кадәр Ю.Т.дә 4 мәчет (беренчесе 18 йөзнең 2 нче яртысында эшли, 1886 да — икенче мәчет, 1911 дә өченче һәм дүртенче мәчет төзергә рөхсәт бирелә). 20 йөз башында балалар мәдрәсә һәм мәктәптә (1834 тә ачыла) белем ала. Бу чорда авыл җәмәгатенең берләштерелгән имана җире 4940 дис.ләп тәшкил итә. Күмәкләштерү чорында Ю.Т.дә Тукай исем. һәм «Урал» к-злары оештырыла, 1931 дә алар «Сталь» бердәм хуҗалыгына берләшә, 1959 да адм. берәмлекләрне берләштергәч, хуҗалык М.Җәлил исемен йөртә башлый. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Кузкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 198, 1859 да — 1204, 1870 тә — 1376, 1897 дә — 1762, 1906 да — 2110, 1913 тә — 2404, 1920 дә — 2266, 1926 да — 1298, 1938 дә — 1459, 1958 дә — 926, 1970 тә — 841, 1979 да — 753, 1989 да — 541, 2002 дә — 522 кеше.

**ЮГАРЫ́ ТЕГЕРМӘНЛЕ́К** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сулы елгасы (Сушаның уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 737 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, 2 мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, ат дирбиясе өчен дуга ясап сату б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.Т.тә мәчет була. 20 йөз башында 3 мәчет, 3 мәктәп, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2071 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 184 ир-ат; 1859 да — 883, 1897 дә — 1449, 1908 дә — 1715, 1920 дә — 1858, 1926 да — 2088, 1938 дә — 2037, 1949 да — 1411, 1958 дә — 1027, 1970 тә — 1388, 1989 да — 947, 2002 дә — 828 кеше.

**ЮГАРЫ́ УКУ́ ЙОРТЛАРЫ́**, халык хуҗалыгы, фән һәм мәдәният өчен югары квалификацияле кадрлар әзерләү б-н шөгыльләнүче махсуслаштырылган учреждениеләр; аларның күбесе алга таба да квалификация күтәрү, белгечләрне яңадан әзерләү буенча эш, ш.у. үз профиле проблемалары буенча фәнни тикшеренүләр алып бара. Эре югары уку йортлары каршында гыйльми дәрәҗәле белгечләр әзерләү өчен аспирантура һәм докторантуралар булдырыла. Югары уку йортларына ун-тлар, академияләр, ин-тлар, консерваторияләр һәм аерым уч-щеләр (мәс., Казан югары артиллерия командирлары уч-щесе) керә. Югары белем бирә торган учреждениеләр җыелмасы «югары мәктәп» термины б-н билгеләнә. Татарстан терр-ясендә Ю.у.й. вазифаларын билгеле бер дәрәҗәдә Идел буе Болгар дәүләтендә барлыкка килеп, алга таба Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында үсеш алган мәдрәсәләр башкара. Алар дини белем бирә һәм, нигездә, мөселман руханиларын, дин белгечләрен һәм галимнәр әзерли. Казанда православие югары уку йортын оештыруга беренче омтылыш 1798 елда була — Казан руханилар семинариясе җирлегендә Казан руханилар академиясе (элеккесе) оештырыла башлый, ләкин тиешле матди ярдәм һәм әзерлекле укытучы кадрлар җитмәү сәбәпле ул бары тик 1818 гә кадәр генә эшли. *Казан руханилар академиясе* кабат 1842 дә ачыла. Анда православие семинарияләре өчен укытучылар һәм дөньяви мәктәпләрдә Ходай канунын укытучылар (өйрәтүчеләр) әзерләнә. Төбәктә беренче классик югары уку йорты булып 1804 тә ачылган Казан император ун-ты санала (к. *Казан университеты*), тиздән ул Россиянең иң зур уку һәм фәнни үзәкләренең берсенә әверелә. 1873 тә *Казан ветеринария институты* булдырыла; 1876 да — *Казан укытучылар институты*, шул ук елны Казан интеллигенциясе инициативасы б-н хатын-кызлар өчен шәһәрдә беренче югары уку йорты — *Казан югары хатын-кызлар курслары* оештырыла. 1917 дә *Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография институты* ачыла.

Окт. рев-циясеннән соң югары уку йортлары системасында укытуның идея-теоретик нигезен тамырдан үзгәртү процесслары бара, югары мәктәпнең идарә системасы үзгәртелә, студентлар составын демократияләштерү һәм пролетарлаштыру өчен көрәш җәелдерелә, югары уку йортлары челтәре шактый үзгәрә. Совет хакимиятенең беренче унъеллыгында ук Казанда яңа Ю.у.й. : 1918 дә — *Казан педагогика институты* (к. *Казан педагогика университеты*), 1919 да — *Казан политехник институты*, *Халык мәгарифе югары институты*, 1920 дә *Шәрекъ академиясе* барлыкка килә. Урта гомуми белеме булмаган эшче һәм крәстиян яшьләренә Ю.у.й.на укырга керү мөмкинлеге ачу өчен, 1919 ның көзеннән алар каршында махсус бүлекләр — *эшчеләр факультетлары* (к. *Казан университетының эшчеләр факультеты*) оештырыла. 1921 нең башында Казанда татар, мари, чуаш секцияләре булган Көнчыгыш халыкларының Югары өлкә партия мәктәбе эшли башлый.

Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң, Казанда югары белем бирү системасын камилләштерү дәвам итә. Студентлар арасында Татарстанның төп милләтләреннән булган яшьләр санын арттыру буенча чаралар күрелә. 1922 дә Казан а.х. һәм урманчылык ин-ты ачыла (к. *Казан аграр университеты*), 1922 нең августында Казан халык мәгарифе югары ин-ты *Шәрекъ педагогика институты* итеп үзгәртелә, ул күпмилләтле Идел-Кама буе өчен югары квалификацияле кадрлар әзерләү һәм гуманитар тикшеренүләр үзәгенә әверелә. Шул ук елда партия һәм совет органнары хезмәткәрләре әзерләү максаты б-н «...Төрки халыклар яшәгән Татарстан һәм башка республикалар өчен» Казанда *Татар коммунистлар университеты* оештырыла (1932 гә кадәр эшли). Илдәге сәнәгатьнең көчәйтелгән үсеше (к. *Индустрияләштерү*), а.х. җитештерүен хуҗалыкны күмәкләшеп алып баруга күчерү (к. *Крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү*) һәм халыкның белем дәрәҗәсен күтәрү өлкәсендәге бурычлар югары белемле белгечләр әзерләүне киңәйтү буенча яңа чараларны гамәлгә ашыруны таләп итә. 1929 да Казан политехник ин-ты яңадан ачыла, 1930 да аннан Коммуналь төзелеш ин-ты аерылып чыга, 1932 дә ул Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-ты итеп үзгәртелә (1941 дә Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле ябыла). 1930 елларда *Казан химия-технология институты* (1930), *Казан медицина институты* (1930), *Казан финанс-икътисад институты* (1931), *Казан авиация институты* (1932) һ.б. оештырыла. 1939 да респ-када беренче төбәк югары уку йорты — *Алабуга укытучылар институты* ачыла. 1940–41 уку елында Казанда 14 югары уку йорты эшли, аларда 12 меңнән артык студент, ш.и. 2 меңнән артык татар укый. Бөек Ватан сугышы елларында, бик зур авырлыкларга карамастан, Ю.у.й. челтәре һәм алардагы проф. — укытучы кадрларның төп нигезе саклана һәм уңышлы эшләвен дәвам итә. Сугыштан соңгы елларда *Казан консерваториясе* (1945), Казан Югары партия мәктәбе (1946, 1960 та ябыла), Казан гражданлык төзелеше инженерлары ин-ты (к. *Казан архитектура-төзелеш университеты*), Бөгелмә укытучылар институты булдырыла.

1960 елларда Казандагы урта хәрби уку йортлары югары хәрби уку йортлары итеп үзгәртелә (к. *Казан югары артиллерия командирлары училищесе*, *Казан югары хәрби командирлар училищесе*).

1969 да Ленинград мәдәният ин-тының һәм Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-ллары ачыла, соңрак алар мөстәкыйль Ю.у.й.на һәм кадрлар әзерләүнең зур үзәкләренә әверелә (к. *Казан мәдәният һәм сәнгать университеты*, *Казан энергетика университеты*).

1980 еллардан Чаллы (к. *Кама икътисади инженерлар академиясе*, Кама физик культура институты), Түбән Кама (*Түбән Кама химия-технология институты*), Әлмәт (*Әлмәт нефть институты*) шәһәрләрендә югары уку йортлары булдырыла башлый.

Татарстанда югары белем бирү системасы үсешендә мөһим этап Татарстанда 1980 еллар ахыры — 1990 еллар башында башлана. Аның үзенчәлекләренең берсе мәгарифнең эчтәлеген радикаль рәвештә яңадан карап-тикшереп чыгу, уку-укыту программаларын идеологияләштерүдән арындыру булса, икенчесе — дәүләтнеке булмаган, ш.и. яңа дини Ю.у.й. барлыкка килү. Алар арасында: *Казан социаль-юридик институт*, *«Тисби» идарә академиясе*, *Икътисад, идарә иту һәм хокук институты*, *Россия ислам институты*, *Казан руханилар семинариясе*, Болгар Ислам академиясе.

2017–18 уку елында ТРда 15 дәүләт Ю.у.й. эшли, аларда 126713 студент укый; 6 ф-лы булган 10 дәүләтнеке булмаган югары уку йортында 23019 студент укый. Проф.-укытучылар коллективларында 7829 кеше, ш.и. 1161 фән. д-ры, 4740 фән. канд., 794 профессор, 2807 доцент эшли.

Чыг.: Культурное строительство в Татарии. 1917–1941: Сб. док. и материалов. К., 1971; Культурное строительство в Татарии. 1941–1970: Сб. док. и материлов. К., 1976; Образование в Республике Татарстан. Стат. сб. К., 2013.

*Әд.:* Балалыкин В.А., Юдин В.П. Высшие учебные заведения Татарской АССР: Справ. К., 1980; Культурная революция в Татарии (1917–1937гг.). К., 1986; История Казани: В 2 кн. К., 1988–91.

*Г.С.Сабиржанов.*

**«ЮГАРЫ́ УҢЫШКА́»**, журнал; к. *«Татарстан авыл хуҗалыгы»*.

**ЮГАРЫ́ УРАТМА́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 51 *км* көньяктарак, Уратма елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 841 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 55 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, китапханә. 1656 дан Бишекле Елга исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Уратма, Гать Васильевская буларак та телгә алына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, сәүдә, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 1840 та Ю.У.да сәүдәгәр Ф.А.Фирсов иганәсенә таш чиркәү төзелә. 20 йөз башында земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2840,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 570, 1897 дә — 1152, 1920 дә — 1569, 1926 да — 1291, 1938 дә — 1124, 1949 да — 736, 1958 дә — 469, 1970 тә — 417, 1979 да — 477, 1989 да — 608, 2002 дә — 907 кеше.

**ЮГАРЫ́ УРЫСБАГА́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Буа елгасыннан 1,5 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 82 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.У.да мәчет, мәктәп, 9 җил тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1735,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Нурлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 255 ир-ат; 1859 да — 604, 1897 дә — 904, 1908 дә — 1170, 1920 дә — 1122, 1926 да — 943, 1938 дә — 660, 1949 да — 298, 1958 дә — 221, 1970 тә — 178, 1989 да — 120, 2002 дә — 114 кеше.

**ЮГАРЫ́ УТА́Р** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы буенда. 2010 елда 112 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 61%, руслар — 39%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Воздвиженский исеме б-н дә билгеле. Беренче булып Керәнле авылыннан керәшен татарлар килеп урнаша, соңрак Казан өязеннән Норма һәм Царёво авылларыннан руслар күченә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 1864–1903 тә Ю.У.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе эшли. 19 йөз ахырында керәшен татарларның бер өлеше исламга кайта. 20 йөз башында Ю.У.да Пётр-Павел чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1906 да ачыла), мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне, тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1340,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1859 да — 440, 1897 дә — 838, 1908 дә — 829, 1920 дә — 769, 1926 да — 812, 1938 дә — 534, 1949 да — 549, 1970 тә — 168, 1979 да — 113, 1989 да — 190, 2002 дә — 184 кеше.

**ЮГАРЫ́ УШМА́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 7 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шушма елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 243 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Околоток 3-я Ушма исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.У.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе эшли. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1920 дә — 281, 1926 да — 340, 1938 дә — 280, 1949 да — 279, 1958 дә — 279, 1970 тә — 285, 1979 да — 271, 1989 да — 228, 2002 дә — 241 кеше.

**ЮГАРЫ́ УШМА́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 18 *км* көнбатыштарак, Ушма елгасы буенда. 2010 елда 460 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 1 нче яртысына кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.У.да мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 су тегермәне, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 824,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 75 ир-ат; 1859 да — 608, 1897 дә — 911, 1908 дә — 1087, 1920 дә — 1069, 1926 да — 1046, 1938 дә — 925, 1958 дә — 721, 1970 тә — 754, 1979 да — 667, 1989 да — 567, 2002 дә — 487 кеше.

**ЮГАРЫ́ ФОМИ́НОВКА** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 45 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куй Елгасы буенда. 2010 елда 240 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 19 йөз башында Курск губернасыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Фоминовка исеме б-н билгеле. 1860 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмгатенең имана җире 2404 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында Ю.Ф.да укырга-язарга өйрәтү мәктәбе, 3 су тегермәне эшли. 1920 еллардан рәсми чыганакларда 2 торак пункт: Югары Фоминовка һәм Түбән Фоминовка (1959 ның 18 ноябрендә авыллар исемлегеннән сызыла) буларак исәпләнә. Күмәкләштерү чорында авылда 4 колхоз оештырыла, 1950 дә Сталин исем. колхозга берләшә, 1957 дә «Кандыз»с-зы бүлекчәсе итеп үзгәртелә. 1988 дә Ю.Ф. «Фоминовка» с-зы составына кертелә, 1996 дан — «Фоминовка» җаваплылыгы чикләнгән ширкәте. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Ивановка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 725, 1897 дә — 1129, 1920 дә — 1284, 1926 да — 530, 1938 дә — 473, 1949 да — 387, 1970 тә — 621, 1979 да — 411, 1989 да — 272, 2002 дә — 297 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЧАЛЛЫ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 35 *км* көньяктарак, Чаллы елгасы (Зәйнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 714 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1724 тән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә, алпавыт утарында көнлекле эштә эшли. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.Ч.да мәчет, мәктәп, су тегермәне була. 1880 ләрдә авыл җәмгатенең имана җире 3236,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 638, 1870 тә — 793, 1897 дә — 943, 1920 дә — 1289, 1926 да — 926, 1938 дә — 834, 1949 да — 942, 1958 дә — 915, 1970 тә — 1099, 1979 да — 1036, 1989 да — 677, 2002 дә — 685 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЧӘКЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 21 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 86 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1920 елларга кадәр Ю.Ч. Иске Чәке авылының татарлар яшәгән өлешен тәшкил итә, аңа 17 йөзнең 1 нче яртысына кадәр нигез салына. 18 йөздән халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашман хезмәтен үти; игенчелек, терлекчелек, мич чыгару, тегү, балта эше, итек тегү б-н шөгыльләнә; Урал алтын приискларына, Донбасс шахталарына китеп эшлиләр. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Иске Чәкедә — мәчет, 1897 дә чиркәү була. 20 йөз башында мәктәп, җәмгать тегермәне, 16 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1052,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Городище волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 946, 1897 дә — 1767, 1910 да — 1719, 1920 дә — 1805, 1926 да — 758, 1938 дә — 664, 1949 да — 525, 1958 дә — 390, 1970 тә — 348, 1979 да — 299, 1989 да — 145, 2002 дә — 107 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЧИШМӘ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 10 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Башта ТАССРның Чаллы кантоны Шәңгәлче волостенда, 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 106, 1949 да — 136, 1958 дә — 124, 1970 тә — 225, 1979 да — 166, 1989 да — 44, 2002 дә — 25 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЧУРА́** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 30 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасы бассейнында. 2010 елда 622 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 1711 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чура, Троицкий исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Троица чиркәве (1864—66 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1868 дә ачыла), тимерче алачыгы, җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1069,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921—22 еллардан Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 104 ир-ат; 1859 да — 454, 1897 дә — 740, 1908 дә — 796, 1920 дә — 877, 1926 да — 768, 1938 дә — 757, 1949 да — 632, 1958 дә — 555, 1970 тә — 615, 1979 да — 625, 1989 да — 564, 2002 дә — 600 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЧЫГТА́Й** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 7 *км* көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 213 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмгатенең имана җире (Түбән Чыгтай авылын да кертеп) 3165 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында Ю.Ч.да мәчет була. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Афонькәсе волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1889 да — 837, 1897 дә — 903, 1920 дә — 1206, 1926 да — 694, 1949 да — 763, 1958 дә — 586, 1970 тә — 562, 1979 да — 466, 1989 да — 276, 2002 дә — 270 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЧЫРШЫЛЫ́** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куак елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 209 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1785 тән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек басу, балта эше б-н шөгыльләнә. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.Ч.да мәчет, 2 су тегермәне эшли. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1116 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Түбән Чыршылы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 12 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 517, 1885 тә — 880, 1910 да — 1239, 1920 дә — 1198, 1926 да — 1028, 1958 дә — 651, 1970 тә — 550, 1979 да — 446, 1989 да — 271, 2002 дә — 249 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЧЫРШЫЛЫ́** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Игәнә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 153 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, ки-

тапханә. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Татар Чыршылысы исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.Ч.да мәчет, мәдрәсә, су тегермәне эшли. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 1082,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Язикәү волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 июленнән — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1859 да — 506, 1897 дә — 731, 1920 дә — 910, 1926 да — 712, 1938 дә — 552, 1949 да — 387, 1970 тә — 307, 1979 да — 264, 1989 да — 180, 2002 дә — 189 кеше.

**ЮГАРЫ́ ШАШЫ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 11 *км* төньяктарак, Шашы елгасы буенда. 2010 елда 142 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Шаши-Спочинок исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Ш.да волость идарәсе урнаша; мәчет, мәктәп, тегермән, 2 вак-төякләр кибете эшли. 1920 гә кадәр Казан губернасының Краснококшайск (1919 га кадәр — Царёвококшайск) өязе Кышлау волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 101 ир-ат; 1859 да — 424, 1897 дә — 548, 1908 дә — 515, 1926 да — 525, 1949 да — 288, 1958 дә — 226, 1979 да — 190, 1989 да — 150, 2002 дә — 134 кеше.

**ЮГАРЫ́ ШӘМӘРДӘ́Н** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 33 *км* көнбатыштарак, Инеш елгасының (Бөренең уң кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 172 кеше (татарлар) яши. Башлангыч мәктәп, клуб. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Ш.дә 2 мәчет, 2 сарык тиресе эшкәртү йорты, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1235,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 138 ир-ат; 1859 да — 506, 1897 дә — 625, 1908 дә — 634, 1920 дә — 828, 1926 да — 574, 1938 дә — 532, 1958 дә — 324, 1970 тә — 244, 1979 да — 214, 1989 да — 175, 2002 дә — 188 кеше.

**ЮГАРЫ́ ШЕПКӘ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 12 *км* көнбатыштарак, Шепкә елгасы буенда. 2010 елда 853 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Кирпеч з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөз ахырында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, мичкә ясау һ.б. кәсепләр б-н шөгыльләнә. Ю.Ш. осталары ясаган чаналар Зәйдә, Бережные Челны (хәзерге Чаллы ш.) һәм Минзәләдә сатыла. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, авылда мәчет, мәдрәсә, су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1749 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү чорында Ю.Ш.дә «Кызыл Татарстан» к-зы оештырыла. 1958 дә авыл «Путь к коммунизму»(1992 дән — «Татарстан») к-зы составына кертелә, 1997 дән — «Шепкә» а.х. товарлары җитештерү кооперативы. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 609, 1897 дә — 1396, 1920 дә — 1720, 1926 да — 1169, 1938 дә — 1096, 1949 да — 1118, 1958 дә — 970, 1970 тә — 1090, 1979 да — 908, 1989 да — 720, 2002 дә — 844 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ЮГАРЫ́ ШӨН** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кәркәүч елгасы буенда. 2010 елда 293 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, нәселле терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөз ахырында Шөн авылыннан (Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны) күченүчеләр нигез сала. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, арба, тәгәрмәч ясау, йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Ш.дә Казан Богородица чиркәве, земство мәктәбе, 3 тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1810,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 74 ир-ат; 1859 да — 574, 1897 дә — 724, 1908 дә — 696, 1920 дә — 730, 1926 да — 798, 1949 да — 608, 1958 дә — 626, 1970 тә — 795, 1979 да — 614, 1989 да — 359, 2002 дә — 368 кеше.

**ЮГАРЫ́ ШУБА́Н** авылы, Балтач р-нында, Балтач авылыннан 11 *км* көнбатыштарак, Шубан елгасы буенда. 2010 елда 367 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Ядегәр исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Ш.да мәчет, мәдрәсә, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1275 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 87 ир-ат; 1859 да — 419, 1897 дә — 539, 1908 дә — 546, 1920 дә — 536, 1926 да — 565, 1938 дә — 454, 1949 да — 256, 1958 дә — 239, 1970 тә — 273, 1979 да — 282, 1989 да — 340, 2002 дә — 359 кеше.

**ЮГАРЫ́ ШҮЛӘҢГЕ́Р** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 46 *км* төньяктарак, Юкәче елгасының уң кушылдыгы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 1710 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Верхний Шелянгур исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Ш.дә мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 112,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 17 ир-ат; 1859 да — 44, 1897 дә — 107, 1908 дә — 116, 1920 дә — 90, 1926 да — 72, 1949 да — 112, 1958 дә — 44, 1970 тә — 46, 1979 да — 28, 1989 да — 7, 2002 дә — 1 кеше.

**ЮГАРЫ́ ШҮРНӘ́К** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 34 *км* төньяк-көнбатыштарак, Вятка елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 28 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Шүрнәк исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 1521 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1887 дә — 537, 1920 дә — 732, 1926 да — 780, 1938 дә — 591, 1949 да — 357, 1958 дә — 265, 1970 тә — 291, 1979 да — 112, 1989 да — 58, 2002 дә — 39 кеше.

**ЮГАРЫ́ ШЫТСУ́** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 14 *км* көньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 350 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп,

мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Ш.да мәчет, мәктәп, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 995,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 31 ир-ат; 1859 да — 253, 1897 дә — 426, 1908 дә — 586, 1920 дә — 644, 1926 да — 593, 1938 дә — 594, 1949 да — 517, 1970 тә — 533, 1979 да — 459, 1989 да — 395, 2002 дә — 380 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЫНДЫРЧЫ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 16 *км* төньяктарак, Казан–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 274 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Ы.да волость идарәсе урнаша; мәчет, мәктәп, почта бүлекчәсе, җил тегермәне, тимерче алачыгы, 4 вак-төякләр кибете эшли. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 115 ир-ат; 1859 да — 508, 1897 дә — 867, 1908 дә — 1047, 1920 дә — 866, 1926 да — 729, 1938 дә — 562, 1949 да — 481, 1958 дә — 448, 1970 тә — 386, 1979 да — 313, 1989 да — 253, 2002 дә — 290 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЫРГА́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 31 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ырга елгасы буенда. 2010 елда 187 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1647 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1850 елларда поташ з-ды эшли. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, тегермән, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1191 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 28 ир-ат; 1859 да — 450, 1897 дә — 708, 1908 дә — 753, 1920 дә — 931, 1926 да — 1005, 1949 да — 711, 1958 дә — 767, 1970 тә — 697, 1989 да — 365, 2002 дә — 249 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЭСТӘРЛЕ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 35 *км* көнчыгыштарак, Эстәрле елгасы буенда. 2010 елда 536 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Эстәрлетамак, Усман исемнәре б-н билгеле. 17–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ю.Э.дә мәчет эшли. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; 2 мәчет, 2 су тегермәне була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3000 дис.тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Эстәрлетамак волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 1457, 1897 дә — 1628, 1920 дә — 1704, 1926 да — 1128, 1938 дә — 1420, 1949 да — 904, 1958 дә — 849, 1970 тә — 906, 1979 да — 770, 1989 да — 605, 2002 дә — 571 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЮМЬЯ́** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 25 *км* көнбатыштарак, Оштырма елгасының (Вятканың уң кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 230 кеше (удмуртлар) яши. Башлангыч мәктәп, клуб. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 16 йөз ахырында Иске Юмья авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон тетү һәм киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Ю.да ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 541,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 28 ир-ат; 1859 да — 202, 1897 дә — 299, 1908 дә — 336, 1920 дә — 387, 1926 да — 381, 1938 дә — 415, 1949 да — 336, 1958 дә — 275, 1970 тә — 309, 1979 да — 278, 1989 да — 239, 2002 дә — 255 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЮШАДЫ́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 20 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 169 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1704 тән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1641 дис. тәшкил итә. 1917 гә кадәр Ю.Ю. аша Минзәлә–Бөгелмә сәүдә юлы уза, земство почта станциясе эшли. 1931 дә авылда «9 нчы гыйнвар» к-зы оештырыла, 1957 дән — «Урожай», 1965 тән — «Ямашев», 1988 дән «Юшады» с-злары составында. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 221, 1859 да — 373, 1870 тә — 439, 1884 тә — 520, 1897 дә — 657, 1906 да — 743, 1913 тә — 887, 1920 дә — 800, 1926 да — 800, 1938 дә — 627, 1949 да — 383, 1958 дә — 312, 1979 да — 205, 1989 да — 151, 2002 дә — 185 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЯКЕ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 29 *км* көнбатыштарак, Омар елгасы буенда. 2010 елда 203 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.Я.дә мәчет, мәктәп, су тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1807 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кече Кирмән волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 63 ир-ат; 1859 да — 383, 1897 дә — 792, 1908 дә — 920, 1920 дә — 896, 1926 да — 1029, 1938 дә — 618, 1949 да — 483, 1958 дә — 546, 1970 тә — 604, 1979 да — 485, 1989 да — 288, 2002 дә — 255 кеше.

**ЮГАРЫ́ ЯХШЫ́Й** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 41 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сикия елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 202 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. Ю.Я. мәчете турында беренче тапкыр 1854 тә телгә алына. 1867 дән аның каршында мәктәп эшли. 20 йөз башында ашлык саклау-сату кибете була. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 128, 1859 да — 304, 1870 тә — 341, 1884 тә — 509, 1906 да — 759, 1913 тә — 545, 1920 дә — 528, 1926 да — 473, 1938 дә — 465, 1949 да — 527, 1958 дә — 322, 1970 тә — 361, 1979 да — 280, 1989 да — 203, 2002 дә — 203 кеше.

**Ю́ДИН** Василий Николаевич (16.1.1911, Тәтеш өязе Олы Бисәр а. – 9.1.1995, Казан), тәрҗемәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). 1935 елдан Казанда, ТАССР ХКС каршындагы Татарстан респ-ка радиофикация һәм радиотапшырулар ком-тында чуаш телендәге тапшырулар мөхәррире, 1938–71 дә (бүленеп) «Ленин ялаве» ж-лы

редакциясендә. Г.Бәшировның «Намус» романын, Г.Гобәйнең «Маякчы кызы», Ш.Рәкыйповның «Чәчәкләр сөйли белә», Г.Бакировның «Укытучым» повестьларын, А.Шамов, Г.Әпсәләмов, Г.Минский, Ф.Хөсни, Хәсән Сарьян, М.Хәбибуллин һ.б. хикәяләрен чуаш теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары. Биобиблиогр. белешмәлек. К., 1986.

**ЮДИН** Иван Николаевич (29.2.1922, Лаеш кантоны Кече Кадрәк а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1968), проф. (1969). 1953 елдан Казан ун-тында, КПСС тарихы каф. (1960–63), 1964–70 тә — Казан төзүче-инженерлар ин-тының КПСС тарихы һәм политэкономия каф. мөдире. 1970 тә Мәскәүдә, 1970–91 дә КПСС ҮКның халыкара бүлеге консультанты, Көньяк Йәмәндә СССР Консуллыгы киңәшчесе. Хезмәтләре сәяси хәрәкәтләрнең социаль нигезе, СССРда Коммунистлар партиясенең роле мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Социальная база роста КПСС. М., 1973; Интернациональный принцип в строительстве и деятельности КПСС. М., 1975.

*Әд.:* О кафедре истории // Молодой строитель. 2004. № 8.

**ЮДИН** Михаил Алексеевич (16.9.1893, С.-Петербург — 8.2.1948, Казан), композитор, педагог, проф. (1939), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1945). 1917 елда — Петроград ун-тының табигыять ф-тын, 1923 тә Петроград консерваториясен (А.Житомирскийда композиция классы) тәмамлый. 1918 дән — музыка мәктәпләрендә һәм техникумнарында, 1926–42 дә Ленинград консерваториясендә укыта, бер үк вакытта, 1941–42 дә, Балтыйк флоты сәяси идарәсе каршындагы композиторлар иҗат төркемендә эшли. 1942 дән Казанда яши. 1945 тән Казан консерваториясендә укыта (дирижёрлык-хор ф-ты деканы). Ю. иҗатында төп урынны вокаль-симф. музыка тәшкил итә: ике катнаш хор, солистлар квартеты, балалар хоры һәм симф. оркестр өчен үзе язган текстка «С.М.Киров истәлегенә реквием» («Реквием памяти С.М.Кирова», 1935), Е.Вечтомова шигыренә «Яз һәм шатлык турында җыр» («Песня о весне и радости», 1936), Б.Лихарев шигыренә «Героик оратория» («Героическая оратория», 1937) һ.б. Казанда К.Нәҗми либреттосына «Фәридә» опера-поэмасын (1945), Г.Камал пьесасы буенча «Хафизәләм иркәм» муз. комедиясен (С.Сәйдәшев б-н автордашлыкта, 1943), Ә.Фәйзи шигыренә «Яшь патриотлар» кантатасын (1944) һ.б.ны, хор өчен татар халык җырлары эшкәртмәләрен, татар шагыйрьләре шигырьләренә романслар һәм җырлар (1942–47) һ.б.ны иҗат итә.

*Әд.:* Гиршман Я. Юдин Михаил // Композиторы Татарстана. М., 2009.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ЮДИН** Михаил Николаевич (8.10.1917, Спас өязе Антоновка а. — 2.5.1992, Биектау р-ны Бөреле җәнлек совхозы пос.), зоотехник, а.х. җитештерүен оештыручы, ТАССРның атказ. зоотехнигы (1960). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1939). 1942 елдан Казакъстан ССРда: 47 нче ат заводында, 1943 тән Төньяк Казакъстан өлкәсенең Тарангун, 1944 тән Явлинка совхозларында эшли. 1946–68 дә Биектау р-ны Бөреле җәнлек совхозында, 1953 тән директор. 1968–77 дә Татарстан «Зверопром» тресты директоры. Ю. эшләгән чорда трестта 6 яңа җәнлек совхозы («Әлмәт», «Матюшино», «Раифа», «Нагорный», «Туйма», «Восточный») барлыкка килә, җәнлек асрау өчен өстәмә урыннар булдырыла, җәнлек тиреләре сату арта (ак төлке тиресе — 1,3 тапкыр, кролик — 1,8, чәшке — 4 тапкырга якын, ш.и. стандарт-кара чәшке — 3, энҗесыман — 18, көмешсыман зәңгәр — 7,8, сапфир — 5, ак 2 тапкыр). 1959–63 тә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЮДИН** Тихон Иванович (2.6.1879, Тула губ., Крапивна ш. (Крапивна Церковь) — 19.10.1949, Мәскәү), психиатр, мед. фән. д-ры (1922), Украина ССРның атказ. фән эшлеклесе (1941). Мәскәү ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1903), шунда ук проф. В.П.Сербский җитәкчелегендәге психиатрия клиникасында калдырыла. 1907–14 елларда Харьков земство психиатрия хастаханәсендә. 1914–24 тә Мәскәү Канатчиково дачасы психиатрия хастаханәсендә. 1924–32 дә Казан ун-тында: психиатрия каф. профессоры, бер үк вакытта Казан округ психиатрия дәваханәсе директоры, 1928 дән мед. ф-ты деканы. 1929–31 дә Казан невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыяте рәисе, «Казанский медицинский журнал» мөхәррире (1929–31). 1932 дән Бөтенукраина психоневрология академиясе Клиник ин-ты директоры, 1937 дән Украина психоневрология ин-ты директоры, соңрак — директор урынбасары, 2 нче Харьков мед. ин-ты директоры урынбасары. 1945 тән 3 нче Мәскәү мед. ин-тының психиатрия каф. мөдире. Хезмәтләре психик авырулар генетикасына карый.

Хезм.: Евгеника. К., 1925; Психопатические конституции. К.,1926.

*Әд.:* Галачьян А.Г. Т.И.Юдин как основоположник русской и советской клинической генетики // Невропатология и психиатрия. 1965. Вып. 12.

**ЮДИН** Янис Андреевич (5.1.1884, Лифляндия губ. — 12.8.1918, Красная Горка тимер юл станциясе, хәзер Юдино), Кызыл Армия командиры. Валмиер укытучылар семинариясен тәмамлагач (1904), Виеталв министрлык мәктәбендә (Лифляндия губ.) укытучы булып эшли. Революцион хәрәкәттә катнаша. 1905–07 еллар рев-циясе чорында сугышчан дружина әгъзасы. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша; 4 нче Видзем латыш укчылары полкында хезмәт итә; подпоручик. 1917 дә Латыш укчылары полклары советы башкарма ком-тына депутат итеп сайлана: юридик комиссия рәисе урынбасары, килештерү-тикшерү бүлеге рәисе. 1918 дә 3 нче латыш совет бригадасы, Петроград җыелма отряды командиры. 1918 нең августында Көнчыгыш фронтта Кызыл Армиянең сулъяк ярдагы гаскәрләр төркемен җитәкли. Казан янында Кызыл Горка тимер юл станциясе тирәсендә барган сугышта һәлак була (соңыннан Ю. истәлегенә исеме үзгәртелә); Казанның Киров р-нындагы посёлок аның исеме б-н атала.

*Әд.:* Кондратьев Н.Д. Комбриг Юдин. К., 1958; Юдин Ян Андреевич // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ЮДИНО КҮЛЕ** (Карьер күле), Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасының югары террасасында, «Аккош күле» урман паркы кырыенда (Казанның Киров р-ны) урнашкан. 1980–85 елларда Юдино посёлогының төньяк-көнчыгыш ягындагы ком карьерында барлыкка килә. Су өслегенең мәйданы 18 *га* (карьер мәйданы 38 *га*). Суының күләме 2600 мең *м*³. Озынлыгы 680 *м*, иң зур киңлеге 340 *м*. Уртача тирәнлеге 14,5 *м*, иң зур тирәнлеге 16 *м*. Формасы озынча түгәрәк. Ярлары текә, урыны б-н кыялы, нарат урманы б-н капланган; төньяк яры сөзәгрәк, ярда ком эшкәртү эшләре бара. Күбесенчә грунт сулары исәбенә туена. Суы йомшак, җиңелчә минеральләшкән (260 *мг/л* га кадәр). Үтә күренмәлелеге 0,5–0,7 *м*. Яшькелт төстә (икенче исеме — Зөбәрҗәт күле шуңа бәйле). Ю.к. суы Аккош күлләре системасын су б-н тутыру өчен файдаланыла. Ял итү урыны. Көнбатыш өлешендәге ярда Казан балалар тимер юлының «Изумрудный» станциясе урнашкан.



Юдино күле.

**ЮДИНО РАЙОНЫ**, ТАССРда. 1938 елның 4 августында оештырыла. Үзәге — шәһәр тибындагы Юдино посёлогы. 1920 гә кадәр район терр-ясе Казан губернасының Казан өязенә керә, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында, 1927 дән — ТАССРның Арча кантоны һәм Казан авыл р-нында, 1930 дан — Казан авыл һәм Дөбъяз р-ннарында. 1940 та мәйданы 953 *км*² була, 62,5 мең кеше яши, 2 шәһәр һәм 24 авыл советын, 120 торак пунктны берләштерә. 1956 да районның мәйданы — 816,8 *км*², 3 шәһәр (ш.и. 1 се авыл советы хокукында) һәм 19 авыл советы, 97 торак пункт исәпләнә. Район үзәге Яшел Үзән шәһәренә күчү сәбәпле, 1958 нең 16 июлендә Ю.р. Зеленодольск (хәзер Яшел Үзән) р-ны дип үзгәртелә.

**ЮДИНО ТӨЗЕЛЕШ КОМЫ ЧЫГАНАГЫ**, Юдино тимер юл станциясеннән 1,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 1950 елда ачыклана һәм тикшерелә. Файдалы катлам Идел елгасының 1 нче — 2 нче тугай асты террасалары утырмаларына туры килә, вак һәм уртача бөртекле аксыл соры кварц комнарыннан тора. Уртача калынлыгы 23 *м*. М100–150 маркалы силикат кирпеч җитештерү өчен 1996 га кадәр файдаланыла.

*Г.Н.Бирюлёв.*

**ЮЕ́Ш КӨРНӘЛЕ́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 8 *км* көнбатыштарак, Көрнәле елгасы буенда. 2010 елда 710 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 78%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ит терлеге асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1710–11 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.К.дә мәчет, җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 266 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Алексеев волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1921 — 22 дән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 65 ир-ат; 1859 да — 937, 1897 дә — 719, 1908 дә — 975, 1920 дә — 927, 1926 да — 585, 1938 дә — 631, 1949 да — 586, 1958 дә — 718, 1970 тә — 509, 1979 да — 531, 1989 да — 557, 2002 дә — 698 кеше.

**ЮЕ́Ш КӨРНӘЛЕ́ КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Көрнәле елгасының (Кама елгасының сул кушылдыгы) түбәнге агымы буенда, Алексеев р-ны Юеш Көрнәле авылыннан көньякта урнашкан. 1960 елда Т.А.Хлебникова, 1970 елларда Е.П.Казаков, 1990 елларда К.А.Руденко һ.б. тарафыннан тикшерелә. Таш һәм бронза гасырлар туктаулыкларын, Имәнкискә һәм Болгар археол. культуралары торулыкларын, каберлекләрне һ.б.ны үз эченә ала. Болгар истәлекләренең берсендә алтын һәм көмеш зәркән эшләнмәләр хәзинәсе (5 үрелгән беләзек, үрдәкле 2 чигә алкасы һ.б.) табыла. Сәүдә-һөнәрчелек торулыгы булган Алексеев VI авыллыгы (Болгар чоры) өйрәнелә. Песчаный остров авыллыгында (Алтын Урда чоры) 14 йөзгә нисбәтле әйберләр (көзге, пычак, асылмалар һ.б.) табылган, соңгы чор төрки күчмә кабиләләр тарафыннан калдырылган мәҗүси кабер тикшерелә. Хәзерге вакытта Ю.К.к.ның күп кенә истәлекләре Куйбышев сусаклагычы сулары б-н юылган яки Кама аркылы күпер салганда ком б-н капланган.

*Әд.:* Хлебникова Т.А. Ещё одна находка болгарских ювелирных изделий // Советская археология. 1963. № 1; Археологические памятники Центрального Закамья. К., 1988; Казаков Е.П., Руденко К.А. Булгарские селища Алексеевской округи // Алексеевский район: История и современность. К., 2000; Руденко К.А. Материальная культура булгарских селищ низовий Камы XI – XIV вв. К., 2000; шул ук. VI Алексеевское селище. К., 2000.

*Е.П.Казаков.*

**ЮЕШЧӘЛӘ́Р** (Ceratopogonidae), парканатлылар отрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. Озынлыгы 0,5–4 *мм*, бөкре гәүдәле, хортумчыгы озын, канат өсте тимгелле. Якынча 4 мең төре билгеле, Россиядә 160 лап төре теркәлгән. Киң таралганнар. Алар аеруча тайга һәм урман зоналарында күп. Зур елга үзәнләре һәм дельталары, сазлыклы урман терр-яләре, картайган, ауган агачлары күп булган аз үзләштерелүче, черүче түшәлмәле урманнар гадәти тереклек итү урыны булып тора. Татарстан терр-ясендә Ю. билгеле бер тирәлектә очрый: Иж һәм Вятка (Көнчыгыш Кама алды) елгаларының Кама-Ык (Көләгеш түбәнлеге) һәм Агыйдел тугайларындагы тамагы өлешендә. Culicoides ыругыннан: C. stigma, C. pulicarius (чагар Ю., яки чагар озынборынчык), C. Nubeculosus күпсанлы төрләр булып санала. Ю. майдан сентябрьгә кадәр, караңгылы-яктылы вакытта яки төннең беренче яртысында активлар. Гадәттә, сезонга 1–2 буын җитлегә. Ю. күкәй һәм личинка фазасында кышлыйлар. Ю.нең тешләве кешедә һәм хайваннарда көчле кычыту тудыра, алар күпләп һөҗүм иткәндә, йорт хайваннарының авырлыгы һәм сөт бирүчәнлеге кими. Кешедә һәм хайваннарда төрле авыру (гемоспоридоз, омхоцероз, энцефалит, түләрәмә) кузгатучыларны таратырга мөмкиннәр.

*В.А.Бойко.*

**ЮЗЕ́ЕВ** Илдар Гафур улы (3.1.1933, БАССРның Яңавыл р-ны Ямады а. – 21.12.2004, Казан), шагыйрь, ТАССРның, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1979, 1983), ТРның халык шагыйре (1993). Казан пед. ин-тын (1954), Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1973) тәмамлый. «Пионер» ж-лында җаваплы сәркәтип (1954–66), «Чаян» ж-лында әдәби хезмәткәр (1966–67), ТАССР Язучылар берлегендә әдәби консультант (1967–71), «Казан утлары» ж-лында поэзия бүлеге мөдире (1973–76), ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисенең яшь авторлар б-н эшләү буенча урынбасары (1977–87) булып эшли. РСФСР Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы (1985).

1950 еллар ахырында әдәбиятка шагыйрь-романтик буларак килеп керә. Ю.ның башлангыч иҗатына гражданлык һәм публицистик сыйфатлар хас; күпчелек шигырьләре диалог формасында иҗат ителә. «Таныш моңнар» (1955), «Фәрит-Фәридә» (1959), «Миләүшә» (1965) поэмаларының, «Яшь наратлар» (1965) шигырь җыентыгының төп мотивы — туган җиргә мәхәббәт. 1960–70 елларда шагыйрьләр Мөхәммәдъяр, Г.Тукай, Һ.Такташ, Х.Туфанга багышлап шигырьләр яза. «Таймас» (1961), «Язылмаган поэма» (1964), «Өчәү чыктык ерак юлга...» (1965) поэмаларында кеше рухының бөеклеге, хөрлеге, тормышны сөю темасына мөрәҗәгать итә. 1970–80 елларда Ю. иҗатында фәлсәфи башлангыч көчәя. Аның игътибарын галәм, яшәү һәм үлем, мәхәббәт мәсьәләләре җәлеп итә («Мин табарга тиеш», 1975; «Әй, кеше!», 1976; «Салкын җирне җылыткандыр кеше», «Диңгезнең ярлары бик ерак», икесе дә — 1977; «Таш диварлар авазы», 1973; «Таш кала фаҗигасе», 1988; «Өзелгән тәсбих», 1989). «Соңгы төн» (1972), «Очты дөнья читлегеннән...» (1980) поэмаларында шагыйрьгә хас шартлы символика алымы көчәя. Аллегориягә нигезләнгән «Мәңгелек белән очрашу» (1982) поэмасында авторның дөньяга антропоцентрик караштан баш тартуы чагылдырыла, җәмгыятькә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә бәя бирелә. «Гашыйклар тавы» (1986) поэмасында кеше рухының бөеклеге гәүдәләндерелә. Ю.ның 1990–2000 еллар иҗатында милли тема көчәя, шагыйрь татар халкы язмышы турында уйлана («Мин нигә гафил булдым?», 1992; «Хакыйкатьне тулы ачалмыйча...», 1994; «Сагышлы мирас», 1995 шигырьләре һ.б.). Драма әсәрләрендә Ю. еш кына гаилә, милләт, тарихи хәтер, тирә-якны саклау мәсьәләләренә мөрәҗәгать итә. Драматургның «Янар чәчәк» (1961 дә куела), «Кыр казлары артыннан» (1976 да куела), «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз» (1983 тә куела), «Мәкәрҗәгә барган идек» (1988 дә куела), «Ак калфагым төшердем кулдан...» (1990 да куела), «Безнең әти мировой» (1991 дә куела), «Сөйгәнемнең туган көне» (1992 дә куела), «Гашыйклар тавы» (1992 дә куела) һ.б. пьесалары буенча куелган спектакльләр Татар акад. театры, Татар драма һәм комедия театры һәм Россиянең күп кенә милли театрлары сәхнәләрендә зур уңыш б-н бара. Бөтенроссия милли театрлар фестивалендә «Сандугачлар килгән безгә» пьесасы буенча Тува рус драма театры тарафыннан куелган спектакль өчен театр коллективы һәм пьеса авторы 1 нче дәрәҗә диплом б-н бүләкләнә.



И.Г.Юзеев.

Ю. балалар өчен дә шигырьләр иҗат итә («Аю сатам, кем ала?», 1999; «Бәби Ай», 2003); шагыйрьнең әсәрләренә көйләр языла: «Яшь наратлар» (Җ.Фәйзи көе), «Төнбоек» (Л.Айтуганов көе), «Мәтрүшкәләр» (А.Гыйлаҗев көе) һ.б.; «Ерактагы кәккүк авазы» (комп. Р.Кәлимуллин) операсына либретто авторы. Ю. әсәрләре рус, башкорт телләренә тәрҗемә ителә. М.Җәлил исем. Татарстан комсомолы бүләге (1968), ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1980) лауреаты. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә (1986).

*Ә с ә р.:* Сайланма әсәрләр: 5 томда. К., 2003.

*Әд.:* Поварисов С. Моң эчендә асылташ // Казан утлары. 2003. № 1; Илдар Юзеев: Истәлекләр, әңгәмәләр, шигырьләр. К., 2008; Мустафин Р. Соловьи прилетают по одиночке // Образ времени. К., 1981.

*Н.М.Йосыпова.*

**ЮЗЕФО́ВИЧ** Якуб Давидович (12.3.1872, Гродно губ. — 5.7.1929, Эстония, Тарту ш.), хәрби эшлекле. Польша-Литва татарларыннан. Михаил артиллерия уч-щесен (С.-Петербург, 1893), Ген. штабның Николай академиясен (С.-Петербург, 1899) тәмамлый. Рус-япон (1904–05), Беренче бөтендөнья, Гражданнар сугышларында катнаша. Полковник (1908), генерал-майор (1915), генерал-лейтенант (1917). 1910–13 елларда Ген. штабның Баш идарәсендә бүлек башлыгы. 1914–17 дә Кавказ җирле халыклар атлы дивизиясе, 2 нче кавалерия корпусы штаблары башлыгы. 1917 дә 12 нче кавалерия дивизиясе, 26 нчы корпус командиры, 12 нче армия б-н командалык итә. 1917 нең ахырында ак-


Н.Г. Юзиев.


Я.Д. Юзефович.

лар хәрәкәтенә кушыла, 1918 нең җәендә генерал А.И.Деникинның Иреклеләр армиясе сафына баса. 1919 да барон П.Н.Врангельнең Кавказ армиясе штабы башлыгы, 5 нче кавалерия корпусы командиры. 1920 дә 3 нче рус армиясе формалашу сәбәпле, чит илгә чыгып китә. Эмиграциядә Тартудагы үз утарында яши. Георгий кораллы, 1 нче, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 4 нче дәрәҗә Изге Георгий, 1 нче, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав, ш.у. чит ил орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* З а л е с с к и й К.А. Кто был кто в Первой мировой войне. М., 2003; Г р и ш и н Я.Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

**ЮЗИ́ЕВ** Айдар Нил улы (7.7.1958, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1998), проф. (2004). ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2018). Ленинград ун-тының көнчыгыш ф-тын тәмамлаганнан соң (1980), СССР ФА Казан ф-лының Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1996 елдан ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исем. Тарих ин-тында эшли. 2000–05 тә Татар гуманитар ин-тының филос. һәм социол. каф. мөдире. 2005–06 да Казан социаль-юридик ин-тында фәнни эшләр буенча проректор. 2006 дан Россия гадел хөкем академиясенең Казан ф-лында гуманитар социаль-икътисади фәннәр каф. мөдире. Хезмәтләре татар фәлсәфи фикере тарихы, ш.и. Ш.Мәрҗанинең хезмәтләрен тәрҗемә итү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Мировоззрение Ш.Марджани и арабо-мусульманская философия. К., 1992; Татарская философская мысль конца XVIII – XIX вв. К., 2001; Философская мысль татарского народа: основные направления развития (X – нач. XX вв.). К., 2007; Хусаин Фаезхан — первый татарский просветитель. Н. Новгород, 2011 (автордаш).

**ЮЗИ́ЕВ** Ибраһим Ибнеәмин улы (1869, Тәтеш өязе Бакырчы а. — 25.10.1912, Казан), гравёр, китап басу остасы. Хәреф җыю эшенә әтисе эшләгән Чирковлар басмаханәсендә өйрәнә. 1890 елдан Б.Л.Домбровский басмаханәсендә хәреф җыючы; 1897 дән И.Н.Харитонов басмаханәсендә, гравёр-хәреф коючы (1900 дән); 1910–12 дә Кәримовлар басмаханәсендә. Г.Камал б-н бергә 30 төргә якын татар шрифтлары ясый, алар рәсемнең матурлыгы һәм үлчәмнәре б-н аерыла, шрифтларның 20 дән артыгы 1909 да ук Харитонов басмаханәсендә китап басуда кулланыла. Алга таба Ю. татар басмасы өчен яңа шрифтларны үзе генә эшли.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

**ЮЗИ́ЕВ** Нил Гафур улы (10.1.1931, БАССРның Яңавыл р-ны Ямады а. – 11.9.1996, Казан, Биектау р-нының Сасмак авылында җирләнә), әдәбият галиме, әдәби тәнкыйтьче, филол. фән. д-ры (1974), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1981). Казан ун-тын тәмамлый (1953). 1956 елдан «Совет әдәбияты» ж-лында, 1960 тан Казан ун-тында, 1973 тән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли (1987 дән кульязмалар һәм текстология бүлеге мөдире, 1991 дән проф.). Тикшеренүләре татар әдәбияты тарихына һәм теориясенә, әдәбиятның башка сәнгать төрләре б-н элемтәләренә багышлана. Ю. җитәкчелегендә татар әдәбияты классиклары әсәрләренең күптомлы җыелмалары әзерләнә һәм нәшер ителә, татар халкының кульязма китаплары, язма истәлекләре, милли мәдәният эшлеклеләренең шәхси архивлары туплана һәм фәнни яктан өйрәнелә. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1974). «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Муса Җәлил поэмалары. К., 1960; Тормыш поэзиясе. К., 1961; Шигырь гармониясе. К., 1972; Хәзерге татар поэтикасы. К., 1973; Шигърият дөньясы. К., 1981; Татар шигыре. К., 1991.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**ЮКАМЕ́Н РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1929 елның 15 июлендә оештырыла. Мәйданы — 1020 *км*². Үзәге — Юкамен авылы (Ижевскидан 177 *км* төньяктарак). Халкы — 8821 кеше (2017). Татарлар саны: 1891 дә — 3832, 1920 дә — 4707, 1939 да — 4614, 2002 дә — 1691 кеше. Ю.р. терр-ясендә татарлар Казан ханлыгы яулангач урнаша башлый, һәм бу берничә этапта бара. Татарларның төп шөгыле — сөрүлекле игенчелек. Көтүлекле-аранлы терлекчелек һәм ш.у. а.х. продукциясе эшләп чыгару б-н бәйле кәсепләр (йон тетү, киез итек басу, җитен эшкәртү, киндер туку, чабата үрү, агач эшкәртү) икенчел роль уйный. Татарларның бер өлеше Пермь губернасында, Вятка губернасының Сарапул өязендәге аракы з-дларында эшли, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1917 дә татарлар Вятка губернасы Глазов өязенең 22 торак пунктында, ш.и. Ёжово волостеның — 11, Юма волостеның — 10, Сюрзянь волостеның 1 авылында яшиләр. Ю.р.ның 9 авылында татарлар гына, 13 ендә катнаш халык: 10 ысында — татарлар, бисерманнар, 2 сендә — татарлар, удмуртлар, 1 сендә татарлар, бисерманнар һәм руслар яши. 1744 тә беренче тапкыр район терр-ясендәге мәчет (Починки а.) телгә алына, 1826 да 2 җамигъ мәчет эшли (Починки һәм Палагай а.), 1891–1901 дә тагын 2 мәчет (Мөрсәлим (Верхний Дасос) һәм Шәфи а.), 1907 дә 4 мәчет (Тегермән (Татарские Ключи), Кече Вениж, Кесшур, Засеково а.) ачыла. 1917 дә хәзерге Ю.р. терр-ясендә 8 мәчет һәм 5 мөселман гыйбадәтханәсе (1930 елларның 1 нче яртысында ябылалар) була, барлык мәчетләр каршында мәктәпләр эшли. 1914 тә Палагай авылында рус-татар мәктәбе ачыла (соңрак Починкига күчерелә). 1920 еллар башында татарлар кайбер авыллардан китәләр. 1929 да алар Вотяк автономияле өлкәсендәге Ёжово (7), Святогорск (3), Юкамен (9) волостьларының 19 торак пунктында яшиләр. 1950 елларга кадәр Палагай авылында тулы булмаган урта татар мәктәбе, Засеково, Иманай, Кесшур, Кече Вениж, Починки, Тегермән, Шәфи авылларында башлангыч татар мәктәпләре эшли. 1980 еллар башында Мавлеево, Югары Солшур, Юнусенки, Зяглуд (соңгы 2 авыл халкы яшәүчеләре булмаган рус авылы — Одинцыга күченә) авыллары юкка чыга; Кече Палагай һәм Зур Палагай авыллары Палагай авылына берләшә. Татарлар, тупланып, Атабай, Мөрсәлим, Засеково, Иманай, Кесшур, Кече Вениж, Одинцы, Палагай, Починки, Тегермән, Шәфи авылларында яшиләр. Ю.р.нда Татар мәдәнияте үзәге эшли. Починки, Засеково һәм Палагай авыллары мәктәпләрендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Шушы авыллар мәдәният йортлары каршында — фольклор коллективлары, Починки һәм Тегермән авылларында мәчет эшли.

*Әд.:* С ы р к и н а И.А., К а с и м о в а Д.Г. Загадки незагадочного народа: ист.-этногр. очерк о чепецких татарах. Глазов, 1994; К а с и м о в а Д.Г. Семейная обрядность чепецких татар (середина XIX – XX вв.). Ижевск, 2003.

*Д.Г.Касыймова.*

**ЮКАЧЁВА** Раушания Хөснетдин кызы (18.2.1959, Питрәч р-ны Күн а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2009). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1981), Әлмәт татар драма театрына җибәрелә. 1983 елдан Татар акад. театры актрисасы; бер үк вакытта, 1989–99 да, театр каршындагы «Балачак» төркемен җитәкли, 1998–2001 дә театр директоры урынбасары, 2002–05 тә Казан шәһәр филармониясе директоры, 2011–16 да Казан актёрлар йорты директоры. Зөлфия (шул исем. әсәр буенча, К.Әмиров), Сәрби, Зөһрә («Яшь йөрәкләр», «Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш), Шәмсекамәр (шул исем. әсәр буенча, М.Әблиев), дәртле Фирдәвес («Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре», М.Гыйләҗев), энергияле, шат күңелле Саҗидә («Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин) рольләрен йомшак лиризм б-н башкара. Истә калырлык аеруча зур рольләре: Гайни («Бәхетсез егет», Г.Камал), Наташа («Һаваларда йолдыз», М.Горький), Әминә («Ләйсән ире Хәсән», Ю.Сафиуллин), Сәкинә («Мирас», Г.Каюмов), Мәрфуга («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Ландыш («Суган чәчәге», И.Зәйниев). Ю. башкаруында билгеле бер чор билгеләрен йөрткән социаль героиня образлары ышандырырлык гәүдәләнә: тынгысыз Саҗидә («Килә ява, килә ява...», «Ява карлар, ява


Р.Х. Ю к а ч ё в а Зөһрә ролендә («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш).

карлар...», З.Хәким), иркә, күңелсезлектән интегүче Танай («Җирән чичән һәм Карачәч сылу», Н.Исәнбәт) һ.б. шундыйлардан. Мәрфуга («Саташкан сандугач», Р.Зәйдулла) ролендә актриса матур тышкы кыяфәте һәм стильле костюмнары артына исәп-хисапчыллык, прагматик акыл һәм туң йөрәклелек яшеренгән бизнес-леди образын тудыруга ирешә. Ю. театр сәхнәсендә ш.у. Айшә («Без китәбез, сез каласыз», Т.Миңнуллин) Руфия («Бичура», М.Гыйләҗев), Маша («Боз астында дулкын», Ә.Т.Рахманколов), Нина («Тол ханымда тукталыш», Э.Лабиш), Мәликә («Банкрот», Г.Камал), Бикә («Ут күршеләр», С.Юзеев), Зөһрә («Курчак туе», М.Гыйләҗев, Р.Хәмид), Сәвия («Мәхәббәт турында сөйләшик», И.Зәйниев), Кәтернә («Гөргөри кияүләре», Т.Миңнуллин), Клара Измайлова («Ак калфагым төшердем кулдан...», И.Юзеев) һ.б. рольләрне зур уңыш б-н башкара һәм тамашачы ихтирамын казана.


Р.Х. Юкачёва.

*Әд.:* Иляловa И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

*И.И.Илялова.*

**ЮКӘ́** (Tilia), юкәчәләр семьялыгыннан яфрак коючан агачлар ыругы. Якынча 50 төре билгеле, башлыча, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Йөрәксыман яфраклы яки вак яфраклы Ю. (T. cordata), киң яфраклы һәм катнаш урманнарда очрый. Эре яфраклы Ю. (T. platyphyllos) декоратив үсемлек буларак бакча-паркларда үстерелә. 15–25 *м* биеклектәге агач. Тамыр системасы куәтле, тирәндә, үзәк тамырлы. Яшь агачларның кабыгы шома, соргылт-көрән төстә, карт агачларның кәүсәләре яргаланган кабыклы. Ябалдашы шар- яки пирамидасыман, куе яфраклы. Бөреләре шактый зур, йомыркасыман формада, шома һәм ялтыравыклы, чиратлашып ботакчыкларда урнашканнар. Яфрак пластинкалары йөрәксыман формада, шактый гына асимметрияле. Яфрагы пычкы читле. Чәчәкләре вак, аксыл-сары, хуш исле, калкан чәчәк төркеменә җыйналган. Җимешләре — вак, кара диярлек озынча түгәрәк чикләвекчекләр, көз ахырында яки кышын коелалар. Июнь ахыры — июльдә чәчәк аталар. Җимешләре август-сентябрьдә өлгерә.Табигый шартларда Ю. орлыктан, үсенте һәм үрентеләрдән үрчи. Күләгәгә чыдам. Чәчәкләрендә эфир мае, флавоноид, сапонин, органик к-талар, каротин бар. Чәчәк төркемен тирләткеч чара буларак файдаланалар. Яфраклары бактерицид үзлекләргә ия. Үзагачы фанера, мичкә, музыка кораллары җитештерүдә кулланыла; юкәреннән — мунчала; курысыннан төрле әйберләр үрәләр. Декоратив һәм баллы үсемлек. 150 елга кадәр яши.


Йөрәксыман яфраклы юкә.

**ЮКӘЛЕ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 48 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Салкынсу елгасы буенда. 2010 елда 41 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1923 тә Дүсем, Ләшәү-Тамак авылларыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Кармалы волостенда. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 62, 1938 дә — 97, 1949 да — 128, 1958 дә — 80, 1970 тә — 76, 1979 да — 49, 1989 да — 36, 2002 дә — 32 кеше.

**ЮКӘЧЕ́**, Кырбаш елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шыя елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 19,4 *км*. Бассейнының мәйданы 118 *км²*. Мамадыш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Ефремов Починок авылыннан (даими яшәүчеләр юк) 1,5 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Ылыя авылыннан 0,5 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. Ю.нең 0,3 тән 7,7 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км²*. Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 100 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 76 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык катламы 0,095 *м³/с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**ЮКӘЧЕ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 27 *км* төньяктарак, Шыя елгасы (Вятканың уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 229 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, курыс төшерү-мунчала ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Казан Богородица чиркәве, земство мәктәбе (1866 да ачыла), тимерче алачыгы, йон-тукыма ману йорты, казна шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 612,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 72 ир-ат; 1859 да — 367, 1897 дә — 641, 1908 дә — 742, 1920 дә — 789, 1926 да — 561, 1949 да — 429, 1958 дә — 413, 1970 тә — 466, 1979 да — 384, 1989 да — 292, 2002 дә — 250 кеше.

**ЮКСЫ́Л** авылы, Әлки р-нында, район үзәге Базарлы Матак авылыннан 29 *км* көньяк-көнбатыштарак, Үтәк елгасы башында урнашкан. 2010 елда 2 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССР ның Спас кантоны Кузнечиха волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1938 дә — 124, 1949 да — 112, 1958 дә — 119, 1970 тә — 106, 1979 да — 21, 1989 да — 3, 2002 дә — 6 кеше.

**«ЮКСЫЛЛА́Р СҮЗЕ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Оренбург губерна ком-тының пропаганда һәм агитация бүлеге органы. 1920 елның 14 маеннан 1921 гә кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — А.Таһиров. Беренче саны «Юксыллар хакыйкате» исеме б-н чыга. Газета коммунистик идеологияне пропагандалау б-н шөгыльләнә, җирле хакимият органнары боерыкларын һәм карарларын бастыра. Империализм б-н көрәшкә, илне торгызырга чакыра, татар хатын-кызлары һәм татар яшьләренең төбәк конференцияләрен тәфсилләп яктырта. 1921 нең 7 ноябрь саны Окт. рев-циясе юбилеена багышлана.

**«ЮКСЫЛЛА́Р ЧАТКЫСЫ́»**, атналык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. РКП(б)ның Төмән губерна ком-ты органы. 1922 елның июленнән 1923 нең сентябренә кадәр Төмән шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 40 ка якын саны чыга. Мөхәррирләре — Г.Вахитов, М.Уральский, Ш.Мәхмүдов. «Ю.ч.»н оештыру карары РКП(б)ның 2 нче губерна съездында кабул ителә (Төмән, 1922). Газетада яңа икътисади сәясәтне тормышка ашыру, җирле Советларга сайлаулар, татар-башкорт мәдәни-агарту оешмаларының авыр финанс хәле турындагы мәгълүмат урнаштырыла, аларның 1,2,3 нче губерна конференцияләре турындагы хисаплары басыла. «Ю.ч.» авыл тормышын яктырта, а.х.н, аеруча терлекчелекне үстерүне активлаштырырга чакыра. Төбәкнең татар халкын укыту-агарту мәсьәләләренә зур игътибар бирелә; уку йортлары төзергә, аларның хезмәткәрләренә паёк бирергә тәкъдим ителә; милли балалар бакчаларының авыр хәле, татар телендәге китаплар җитмәү буенча борчылуын

белдерә; яшьләрнең скаут хәрәкәтен үстерүне пропагандалый. «Ю.ч.» редакциясе авыл өчен матбугат һәм әдәбият кирәкми дип исәпләгән «Эшче» г-тасы (Мәскәүдә нәшер ителә) б-н бәхәскә керә. Җирле авторларның (Ш.Мәхмүдов, С.Гафури, Госман һ.б.) фельетоннары, хикәяләре һәм шигырьләре басыла. «Яшьләр сәхифәсе» дигән кушымтасы чыга.

**«ЮЛ»**, газета; к. *«Сабан»*.

**ЮЛА́ШЕВ** Әхәт Гайнулла улы (1.5.1928, Казакъстан АССРның Кызыл Урда өлкәсе Жумалак Тургай а.), генерал-майор (1981), җәмәгать эшлеклесе. 1 нче Мәскәү хәрби-авиация элемтә уч-щесен (1948), маршал А.А.Говоров исем. Радиотехника артиллериясе академиясен (Харьков ш., 1957) тәмамлый. 1945–87 елларда СССР Кораллы Көчләрендә. 1974 тән СССР Һава һөҗүменнән саклану гаскәрләре 12 нче аерым армиясенең радиотехника гаскәрләре башлыгы (Ташкент). Әфганстандагы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша (1980). 1987 дән Үзбәкстан һәм Татарстанда ветераннар советларының актив эшлеклесе. 2001 дән Татарстан Республикасының сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары (инвалидлары) җәмәгать оешмасы рәисе. Ветераннарның социаль-хокукый нормаларын саклау буенча дәүләт сәясәтен гамәли тормышка ашыруга һәм гражданнарны патриотик тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен», Дуслык, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр, исемле корал б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000; Лучшие люди России: Энцикл. М., 2005; Генерал Юлашев. Страницы жизни. К., 2013.

**ЮЛБА́Т** авылы, Саба р-нында, район үзәге шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 6 *км* көньяктарак, Казкаш елгасы буенда. 2010 елда 428 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Енбулатово, Ямбулатово исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, тегермән, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1171,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 70 ир-ат; 1859 да — 443, 1897 дә — 692, 1908 дә — 902, 1920 дә — 869, 1926 да — 827, 1938 дә — 725, 1949 да — 529, 1970 тә — 524, 1979 да — 422, 1989 да — 453, 2002 дә — 428 кеше.

**«ЮЛДА́Ш»**, мәгълүмати-танып белү газетасы. 1992 елның 2 апреленнән Казанда атнага 2–3 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Иң беренче татар телле коммерция басмаларының берсе. Оештыручысы — «Юлдаш» г-тасы редакциясе. Мөхәррире — Р.Р.Газизов. Актив авторлары арасында — М.Абдуллин, Н.Вахитов, Ф.Ибраһимова, Р.Мәүзиев, З.Мусина, Ә.Сафиуллин. Басманың максаты — татарларның мәдәни һәм иҗтимагый тормышын яктырту. Язмалар артистлар, язучылар иҗаты, шәһәр һәм авыл тормышына багышлана; журналист тикшеренүләре, укучыларның хатларына җаваплар басыла. Кушымталары: телепрограмма б-н «Дулкын» атналык г-тасы, «Аш-су», «Сәламәт булыйк!», «Дин вә йола» г-талары.

**ЮЛДА́ШЕВ** Алмаз Кыям улы (26.7.1926, Чистай ш. — 5.1.2010, Казан), а.х. җитештерүен механизацияләү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1988), ТР ФАнең мөхбир-әгъзасы (1998), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998), ТАССРның атказ. механизаторы (1976). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), Казан электр техникасы з-дында эшли. 1953–2010 елларда Казан аграр ун-тында, тракторлар һәм автомобильләр каф. мөдире (1962–87), проф. (1987 дән). Төп юнәлеше — билгеләнмәгән йөкләнешле трактор моторының эш процессларын тикшерү. Ю. җитәкчелегендә мотор эше күрсәткечләрен динамик режимда өйрәнү өчен инерциясез приборлар һәм стендлар комплексы булдырыла; моторларның динамик сыйфатламаларын яхшырту һәм машина-трактор агрегатларын рациональ комплектлаштыру юлы б-н трактор һәм автомобильләрнең җитештерүчәнлеген һәм экономиялелеген арттыру буенча тикшеренүләр үткәрелә (нәтиҗәләре илебез з-дларында гамәлгә кертелә). Ю. ТРның техник вузларында рус һәм татар телләрендә белем бирү программасын гамәлгә ашыруга мөһим өлеш кертә. Уйлап табуга авторлык таныклыклары һәм патентлары бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Динамика рабочих процессов двигателя машинно-тракторных агрегатов. К., 1980; Тракторным дизелям экономичность и надёжность. К., 1984 (автордаш); Тракторы и автомобили. М., 1993 (автордаш).

**ЮЛДА́ШЕВ** Әхнәф Әхмәт улы (30.7.1920, Уфа губ., Бәләбәй өязе Кәлшәле а. — 20.7.1988, Мәскәү), тел галиме-тюрколог, филол. фән. д-ры (1966), проф. (1967), БАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1970). Куйбышев пед. ин-тын тәмамлый (1947). 1938–42 елларда БАССРның Баймак р-ны Түбә урта мәктәбендә немец теле укытучысы. 1950 дән СССР ФАнең Тел белеме ин-тында (Мәскәү). Хезмәтләре төрки телләр диалектологиясе, лексикасы, морфологик һәм синтаксик төзелеше, тарихына карый. Ю. төрки фигыльнең сүз ясагыч һәм сүз төрләндергеч категорияләре — төр (вид), юнәлеш, наклонение, модальлек, заман структурасын һәм семантикасын анализлый; хәл фигыльләрне фигыльнең затланышлы формаларына мөнәсәбәтле тасвирлый. «Төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы. Фонетика» («Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Фонетика», М., 1984); «Төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы. Морфология» («Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Морфология», М., 1988) коллектив хезмәтләре мөхәррире һәм автордашы. Фин тюркологы А.Рясяненнның «Төрки телләрнең тарихи фонетикасы буенча материаллар» («Материалы по исторической фонетике тюркских языков», М., 1955) китабын тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Аналитические формы глагола в тюркских языках. М., 1965; Принципы составления тюркско-русских словарей. М., 1972; Соотношение деепричастных и личных форм глагола в тюркских языках. М., 1977.

*Әд.:* Юдакин А.П. Урало-алтайское (тюрко-монгольское) языкознание: Энцикл. М., 2001.

**ЮЛДА́ШЕВ** Кыям (Кыяметдин) Исхак улы (25.12.1890, Казан губ., Чистай өязе Күлбай Мораса а. – 10.11.1955, Казан), шагыйрь. 1907–13 елларда «Мөхәммәдия», «Касыймия» мәдрәсәләрендә укый, аннан соң укыта. 1917 дә Казан өязе укытучылар советы идарәсе рәисе итеп сайлана. 1921–26 да Чистай шәһәрендә яши, район авыл хуҗалыгы берлеге идарәсе рәисе була. 1927–35 тә Татарстан дәүләт нәшрияты, 1935–37 дә «Татжилкооппромснаб» директоры. Матбугаттагы беренче язмалары 1910 елларда басыла. «Зилзилә хикәясе һәм балалар өчен гыйбрәтле шигырьләр» (1912), «Моңлы тавышлар яки моңлы шигырьләр» (1912) шигырь җыентыклары авторы. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Юлдашева Л., Ибраһимова Ф. Мөгаллим шагыйрь // Совет мәктәбе. 1984. № 2.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**ЮЛДА́ШЕВА** Ләлә Кыям кызы (13.9.1921, Чистай ш. — 9.3.2009, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (1981). 1944 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук А.М.Бутлеров исем. химия фәнни-тикшеренү ин-тында (1987 гә кадәр) һәм физик химия кафедрасында (1949–59) эшли. Хезмәтләре стереохимиягә багышлана. Карбонил төркемнәрен, кислород, күкерт, селен, мышьяк, кремний атомнарын үз эченә алган гетероциклларның фәзаи төзелешен һәм молекула эче электроннар үзара тәэсирләшүенең нечкә эффектларын ачыклый. Аларның фәзаи структурасын билгеләүче факторларын өйрәнеп, стереохимия мәгълүматлары нигезендә яңа кушылмаларны максатчан рәвештә синтезлау мөмкинлеген күрсәтә. Кремний, күкерт, селен, мышьяк кушылмаларындагы бәйләнешләр һәм төркемнәрнең полярлыгын һәм полярлашучанлыгын сыйфатлаучы аддитив параметрлар системасын эшли. Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыяте бүләгенә лаек була (1952,1965,1969). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Факторы, определяющие пространственную структуру циклических эфиров // Влияние высших атомных орбиталий на физические и химические свойства соединений переходных металлов. Рига, 1971 (автордаш); Взаимодействие некоторых альфа-дикарбоновых соединений с этандитиолом и пространственное строение образующихся продуктов // Изв. АН СССР. Сер. хим. 1973. № 11 (автордаш).

**ЮЛИА́Н** (13 йөз), Доминик ордены венгр монахы, сәяхәтче. 1230 елларда Дунай венгрларының легендар ватаны — *Бөек Венгрияне* (Magna Hungaria) һәм аларның көнчыгыштагы кабиләдәшләрен — «мәҗүси венгрларны»

эзләү максатында Көнчыгышка сәяхәт кыла. 1235 нең маенда Венгриядән чыгып китә, 1236 ның маенда Идел буе Болгар дәүләтенә килеп җитә, аны «бай шәһәрләре булган бөек һәм куәтле патшалык» дип атый. Юлын дәвам итеп, Әтил елгасы (фаразланганча, Агыйдел елгасы) тирәсендә Ю. «телләре венгр теле булган», даирәләрендә венгрлар б-н килеп чыгыш уртаклыгы турында риваятьләр сакланган кабиләдәшләрен эзләп таба. 1236 ның ахырында Ю. туган иленә кайта. Үз сәяхәте нәтиҗәләре хакында Венгрия короле Бела IV гә һәм Рим Папасы Григорий IX га бәян итә. Ю.ның Бөек Венгриягә икенче сәяхәте 1237–38 дә гамәлгә ашырыла. «Русьның иң кырый чикләренә» җитеп, Ю. болгарлар, «мәҗүси венгрлар» һәм «бик күп патшалыкларның» монгол гаскәрләре тарафыннан яулануы турында белә. Монголлар хакында күпсанлы мәгълүматлар җыеп, Ю. Венгриягә әйләнеп кайта. Ю. хәбәрләре 13 йөзнең 1 нче яртысында Көнчыгыш Европа тарихы буенча мөһим чыганаклардан исәпләнә.

*Әд.:* А н н и н с к и й С.А. Известия венгерских миссионеров XIII–XIV вв. о татарах и Восточной Европе // Ист. архив. 1940. Т. 3.

**ЮЛМӘ́ТОВА** Суфия Фатыйх кызы (2.1.1919, Самара губ., Бөгелмә өязе Бөгелмә ш. — 2.5.2011, Уфа), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1981), проф. (1984), БССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1941). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1949 елдан Казан пед. ин-тында, 1954 тән Казан ун-тында укыта. 1961–96 да Башкорт ун-тында (1962–90 да чит илләр әдәбияты каф. мөдире). Хезмәтләре Р.Роллан, А.Франс, Э.Золя, И.Гёте иҗатларына, 19 йөз ахырында — 20 йөз башында чит ил әдәбиятларындагы сәнгать алымнарына багышлана. Г.Тукай, Л.Н.Толстой әсәрләрен өйрәнә.

Х е з м.: «Очарованная душа» Р.Роллана в свете идейной эволюции писателя. К., 1959; Анатоль Франс и некоторые вопросы эволюции реализма. Саратов, 1978; Новаторство Эмиля Золя. Уфа, 1988; Пути развития реализма в зарубежных литературах конца XIX — начала XX в. М., 1990 (автордаш).

**ЮЛТИМЕ́Р** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Урман Чишмәсе елгасы бассейнында. 2010 елда 364 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1770 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.дә 2 мәчет, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2594 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спиридоновка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1785 тә — 96 ир-ат; 1859 да — 488, 1889 да — 683, 1910 да — 1645, 1920 дә — 1695, 1926 да — 1006, 1938 дә — 805, 1949 да — 640, 1958 дә — 504, 1970 тә — 583, 1979 да — 466, 1989 да — 292, 2002 дә — 362 кеше.

**ЮЛТИМЕ́Р** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 15 *км* төньяктарак, Минзәлә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 307 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.дә мәчет, мәктәп, ашлык саклау-сату һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 858 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Язикәү волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 505, 1897 дә — 857, 1906 да — 990, 1920 дә — 855, 1926 да — 708, 1938 дә — 764, 1949 да — 588, 1958 дә — 513, 1970 тә — 517, 1979 да — 401, 1989 да — 275, 2002 дә — 305 кеше.

**ЮЛ-ТРА́НСПОРТ ТӨЗЕЛЕШЕ́**, автомобиль юлларын, төрле юл-файдалану корылмаларын төзү, реконструкцияләү б-н шөгыльләнүче матди җитештерү тармагы. Юллар төзү эшләре комплексына җир полотносын әзерләү, юл өслеген түшәү, күперләр, туннельләр, җир өстендәге эстакадалар, төрле биеклектәге транспорт чишелешләре, ш.у. аэродромнар төзү керә.

1917 елга Казан губернасы юллар челтәрендә җигүле транспорт хәрәкәте өчен файдаланылган грунт юллар өстенлек итә (25 мең чакрым чамасы). Җөри (Казан — Уфа), Оренбург, Мәскәү, Себер трактларында гомуми озынлыклары 550 чакрымнан арткан таш, вак таш-чуерташ түшәлгән участоклар була. Юллар губерна һәм өяз земство идарәләренең техник бүлекләре (1866 дан), Юл министрлыгының Шоссе юллар идарәсе (1916–17) тарафыннан җирле халык арасында җәмәгать эшләре оештыру нәтиҗәсендә төзелә. 1950 еллар ахырына кадәр Ю.-т.т. халыкның хезмәттә мәҗбүри катнашуы нигезендә башлыча авыл советлары, колхозлар, совхозлар көче б-н, автотранспорт пр-тиеләрен җәлеп итеп гамәлгә ашырыла. Юл эшен үстерү өчен 1929 да РСФСР «Автодор» автомобилизм үсешенә һәм юлларны яхшыртуга ярдәм итү иреклe җәмгыятенең Татарстан бүлеге төзелә. 1930 да илдә юл төзү машиналарын серияләп җитештерү башлана. 1931 дә Ю.-т.т. б-н җитәкчелек итү илнең Үзәк юл-транспорт идарәсе бүлеге буларак оештырылган «Татдортранс» идарәсенә (1987 дән — «*Татавтодор*» проектлау-ремонт-төзелеш берләшмәсе) йөкләнә. 1950 еллар ахырында сәнәгать һәм а.х. үсеше, Татарстанның көнчыгышында яңа сәнәгый районнар барлыкка килү, йөкләр ташуның артуы колачлы Ю.-т.т.нә, махсус пр-тиеләр булдыруга, яхшыртылган юл капламнарын киң файдалануга китерә. 1970 елларда автомагистральләр — төрле биеклектәге транспорт чишелешләре булган юллар төзелә башлый. Гомуми файдаланудагы каты капламлы автомобиль юлларының озынлыгы 1940 та 2600 *км* дан 1960 та 3000 *км* га кадәр арта, 1970 тә — 5209 *км*, 1980 дә — 7496 *км*, 1990 да — 9547 *км*, 2003 тә 12741 *км* тәшкил итә. Гомуми файдаланудагы каты капламлы автомобиль юлларының тыгызлыгы — 1000 *км*² га 187,8 *км* тәшкил итә (Россия буенча уртача 50 *км* чамасы).

2003 кә респ-када барлык автомобиль юлларының озынлыгы 18592,1 *км* га, ш.и. гомуми файдаланудагы юллар озынлыгы 12865,3 *км* га, ведомство карамагындагыларныкы 5726,8 *км* га җитә. Каты капламлы юллар — 18090,6 *км* (ш.и. камилләштерелгән юллар: асфальт-бетон, цемент-бетон, кара чуерташ капламлы юллар — 10539,8 *км*; калганнары — вак таш, шлак материал капламлы һ.б. юллар), грунт юллар — 501,5 *км* автомобиль юллары.

Татарстан терр-ясе буйлап федераль әһәмияткә ия юллар (барлыгы 1086,5 *км*), ш.и. Мәскәү–Уфа (М7 (Волга)), Алабуга–Пермь, Мәскәү–Самара–Чиләбе (М5 (Урал)), Казан–Оренбург (Р239), Казан–Ульянов (Р241), Казан–Йошкар-Ола (А295), Чабаксар–Ульянов (А151), Р175 автомагистральләре участоклары, ш.у. Чаллы–Әлмәт (16А-0003) юлы уза. Халык хуҗалыгында зур әһәмияткә ия юлларга Чаллы–«Бигеш» аэропорты һәм Казанны төньяктан әйләнеп узучы автомагистральләр, Казан–Теләче–Байлар Сабасы–Шәмәрдән, Чистай–Аксубай–Нурлат, Чистай–Түбән Кама, Кама Тамагы–Апас, Кукмара–Мамадыш трассалары һ.б. керә.

1999–2001 дә 71 күпер, 1 һавага күтәрелү-төшү полосасы, 1 юл сервисы комплексы төзелә. 1999–2003 тә 656,7 *км* каты капламлы юллар җәелә. Респ-када Ю.-т.т.ндә өстенлекле юнәлеш буларак авыллар, а.х. пр-тиеләренең үзәк утарлары һәм район үзәкләре арасында асфальт-бетон капламлы автомобиль юллары төзелеше үсеш кичерә (1994 тә 3,1 мең торак пунктның 1,9 меңе генә каты капламлы юллар б-н тоташтырылган була). 2002 дә район үзәкләре б-н 36 торак пункт, ш.и. 23 үзәк утар тоташтырыла. Эре проектлар гамәлгә ашырыла: 2002 дә Саескан Тавы авылы янында Кама елгасы аша автомобиль күперенең беренче, 2016 да икенче чираты файдалануга тапшырыла; Казан — Чаллы трассасы реконструкцияләнә. 2003 тә «Бигеш» аэропортының һавага күтәрелү-төшү полосасын реконструкцияләү төгәлләнә, «Казан» халыкара аэропорты модернизацияләнә.

Ю.-т.т. федераль бюджеттан (14 млрд. сум) һәм респ-ка бюджетыннан (15 млрд. сум) финанслана (2017). 2016 га барлыгы 2500 ләп авыл (ел саен 30 авыл) асфальт юллар б-н тоташтырыла; елга 600 *км* чамасы озынлыкта юллар ремонтлана, уртача 150 *км* озынлыкта төзелә. 2016 да автомобиль юлларының озынлыгы 41933,9 *км*, ш.и. гомуми файдаланудагы юллар 38947,9 *км*, гомуми файдаланудагы каты капламлы юллар 29122,6 *км*, ведомство карамагындагы юллар 2986 *км*; гомуми файдаланудагы каты капламлы автомобиль юлларының тыгызлыгы 1000 *км*² га 430 *км* (Россия буенча 62 *км*).

Респ-када Ю.-т.т. буенча махсуслаштырылган эре пр-тиеләр исәбенә «Татавтодор»

ААЖ, «Камдорстрой» АЖ, «Татарстан күперләре» ҖЧҖ һ.б. керә. Асфальт һәм асфальт-бетон җитештерүче 30 лап завод эшли. Дәүләт ген. заказчысы — *Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының* Юл-транспорт комплексын үстерү баш идарәсе (2001 дән).

*С.Г.Белов.*

**ЮЛТЫ́ЕВА** Нинель Даут кызы (3.2.1926, Уфа ш. — 23.11.2014, Казан), балет артисты, балетмейстер, педагог, проф. (1985), РСФСРның, БРның һәм ТРның халык артисты (1957, 1995, 1996). Санкт-Петербургта Пётр исем. фән һәм сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы. 1949 елда — Ленинград хореография уч-щесен (педагоглар А.Ширяев, М.Романова-Уланова, Е.Ширипина), 1972 дә Ленинград консерваториясенең балетмейстерлык бүлеген тәмамлый. 1941–46 да Башкорт опера һәм балет театры солисты, 1946–66 да Татар опера һәм балет театры солисты, 1969–73 тә баш балетмейстеры. 1972–98 дә Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында хореография кафедрасы мөдире, бер үк вакытта, 1974–77 дә, Каһирә балет труппасында балериналар классы педагогы, баш балетмейстер һәм сәнгать җитәкчесе. 1981–83 тә Каракас шәһәрендәге (Венесуэла) Симон Боливар исем. мәдәният үзәгендә Тереза Кареньо исем. театрның балет труппасы балетмейстер-педагогы, 1988–89 да Каһирә югары балет ин-тының сәнгать җитәкчесе. 1998 дән Казан хореография уч-щесенең сәнгать җитәкчесе. Төп партияләре: Жизель (шул исем. әсәр буенча, А.Адан), Сванильда («Коппелия», Л.Делиб), Одетта-Одиллия, Аврора («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Раймонда (шул исем. әсәр буенча, А.Глазунов), Китри, Никия («Дон Кихот», «Баядерка», Л.Минкус), Тао Хоа («Кызыл мәк», Р.Глиэр), Лауренсия (шул исем. әсәр буенча, А.Крейн), Катерина («Таш чәчәк», С.Прокофьев), Сари («Яшен сукмагы буйлап», К.Ә.Караев), Зәйтүнгөл («Торналар җыры», З.Исмәгыйлев, Л.Степанов), Сөембикә («Шүрәле», Ф.Яруллин), Зарифа («Тау әкияте», А.Ключарёв), Зифа («Кисекбаш», Р.Гобәйдуллин), Раушан (шул исем. әсәр буенча, З.Хәбибуллин) һ.б. 1957 дә чит илләргә (Кытай, Бирма, Вьетнам) гастрольләр б-н бара. Югары проф. хореография техникасы, ул иҗат иткән тирән эчтәлекле сәхнә образлары аны оста биюче буларак ача. Ю.ның Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә куйган балет постановкалары: «Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл» («Лебединое озеро», «Спящая красавица», П.Чайковский), «Баядерка» (Л.Минкус), «Бахчасарай фонтаны» («Бахчисарайский фонтан», Б.Асафьев), «Шүрәле» (Ф.Яруллин); С.Сәйдәшев, А.Ключарёв, Р.Яхин һ.б. музыкасына концерт номерлары; Каһирә балет труппасы өчен «Жизель» (А.Адан), «Дон Кихот» (Л.Минкус), Ф.Шопен музыкасына «Шопениана»; Тереза Кареньо исем. театрның балет труппасы өчен «Аккош күле» («Лебединое озеро», П.Чайковский; 2 нче, 3 нче актлар), А.Бородинның «Кенәз Игорь» операсыннан «Кыпчак биюләре» («Половецкие пляски»), «Гаянэ» балетыннан А.Хачатурянның «Кылычлар белән бию»е («Танец с саблями») һ.б. Башкортстан Респ-касының Салават Юлаев ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Н.Д. Юлтыева.

Ә с ә р.: Адажио моей памяти. К., 2006. *Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Г о р ш к о в В.Н. Нинель Юлтыева: сотни жизней в одной. К., 1996.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ЮЛТЫ́Й** (Юлтыев) Даут Исхак улы (18.4.1893, Оренбург губ., Йомран-Табын волосте Юлтый а. – 1938), язучы, җәмәгать эшлеклесе. Н.Д.*Юлтыеваның* әтисе. Гражданнар сугышында катнаша. Уфа шәһәрендә яши. 1921 елда «Башкортстан» г-тасы, «Яңа юл», «Белем» ж-ллары мөхәррире. Советларның 9 нчы Бөтенроссия съезды делегаты. 1925–26 да Мәскәүдә Кызыл профессорлар ин-тында укый, беркадәр вакыт Үзәк нәшрияттә эшли. 1930 елларда «Октябрь» ж-лы, «Әдәби удар» г-тасы мөхәррире. БАССР Язучылар берлеген оештыручыларының һәм җитәкчеләренең берсе. Матбугаттагы беренче язмалары 1916 да басыла. Иҗатының башлангыч чорына агарту мотивлары, социаль тигезсезлекне фаш итү хас. Алга таба Ю. поэзиясе агитацион-публицистик төсмер ала. «Урал моңдары» (Эстәрлетамак, 1921) беренче поэтик җыентыгы романтик югарылык, заман каршылыкларын сурәтләгәндә гипербола һәм контраст алымнарын куллану б-н аерыла. «Мәйсәрә», «Нефть тураһында әкиәт» (икесе дә — 1932), «Айһылыу» (1933) поэмаларына көрәш һәм иҗади хезмәт пафосы хас. Ю. «Ҡарағол» (1920) трагедиясе б-н башкорт тарихи-көнкүреш драматургиясенә нигез сала. Аның дәвамы — «Мәҡтымһылыу» (1924) пьесасы. «Ҡолансәс» (Уфа, 1925), «Тирмәндә» (1927) һ.б. агитпьесалар авторы. 1930 елларда башкорт театрлары сәхнәләрендә колхоз тормышына («Һин кем?»), тискәре күренешләргә («Аралбаевтар»), тарихи темага («Акшан-батыр») багышланган пьесалары куела. Ю.ның прозасы (хикәяләре, очерклары) чынбарлыкка нигезләнеп үсә, искелек һәм яңалык көрәшен, яңа шәхес формалашуын яктырта. Тарихи-революцион «Ҡан» (1 нче кит., 1934; 2 нче кит., 1936, 1970 тә нәшер ителә) романы авторы. Анда көндәлек стилендә сугыштагы солдат көнкүреше сурәтләнә. Әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә соц. реализм принципларын алга сөрә. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1959; Һайланма әҫәрҙәр: 2 томда. Өфө, 1957.

*Әд.:* Писатели земли башкирской. Уфа, 2006.

**Ю́ЛУШЕВ** Ирек Гали улы (28.4.1934, Пермь өлкәсенең Барда р-ны Танып а.), туфрак белгече, агрохимик, а.х. фән. д-ры (1990), проф. (1992). Пермь а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), Фалёнки селекция станциясендә (Киров өлкәсе) эшли, аның директоры (1960 елдан). 1962–76 елларда һәм 1990 нан Киров а.х. ин-тында (хәзер Вятка а.х. академиясе), агрохимия һәм туфрак белеме каф. мөдире (1993 тән). 1968–72 дә Мали Респ-касының политехник ин-тында (Катибугу ш.) укыта. 1976–90 да Төньяк-Көнчыгыш а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында (Киров ш.), директор урынбасары (1987 гә кадәр), мелиорация лаб-ясе мөдире (1987 дән). Хезмәтләре трансформация, миграциягә һәм гумус, биоген элементлар, авыр металлар, игенчелектә элемент-пычраткычлар балансына, үсемлекләрнең туклануында төп элементларны куллану коэффициентына, чыгым нормативларын эшләүгә карый. Ю. кәсле-көлсу туфракларның экологик типологизациясен нигезли һәм игенчелектә адаптив-ландшафтлы системаларны оештыруның туфрак-агрохимик нигезләрен, Идел-Кама игенчелек төбәгенең туфрак капламы мониторингын эшли. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Система применения удобрений в севооборотах. Киров, 1999; Почвенно-агрохимические основы адаптивно-ландшафтной организации систем земледелия ВКЗП. М., 2005; Агрогруппировка дерново-подзолистых почв для земледельческой практики // Плодородие. 2007. № 4.

**ЮЛЬМЕ́ТЬЕВ** Мөҗип Гариф улы (20.7.1907, Казан губ., Мамадыш өязе Ушма а. — 2.1.1968, Казан), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. зоотехнигы (1967). Татар соц. игенчелек техникумын тәмамлый (1929). 1929–68





Н.Д.Юлтыева: 1. Жизель (шул исем. әсәр буенча, А.Адан); 1. Сөембикә («Шүрәле», Ф.З.Яруллин. 1957) рольләрендә.

елларда Казан а.х. ин-тының уку-укыту хуҗалыгы директоры урынбасары, директоры. СССР ВДНХсында катнаша (1939, 1940, 1941, 1955, 1957, 1966). Ю. җитәкчелегендә уку-укыту хуҗалыгы студентларны җитештерүгә өйрәтүдә, фәнни-тикшеренүләр алып баруда һәм а.х. фәне һәм практикасы казанышларын пропагандалауда нәтиҗәле базага әверелә. Куе сөтле сыерлар көтүен булдыру өстендә эшли, еллык савым уртача һәр сыердан 5–6 мең *кг* тәшкил итә. Ю. Татарстанда терлек азыгы кәбестәсе, терлек азыгы кабагы, «Куузику» гибрид гәрәнкәсе кебек а.х. культураларын гамәлгә кертүне башлап җибәрүче. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының 2 алтын, 1 көмеш һәм 2 бронза медале, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. *И.Н.Афанасьев.*

**ЮЛЬМЕ́ТЬЕВ** Ренат Мөҗип улы (14.12.1940, Казан — 14.4.2009, шунда ук), физик, физика-матем. фән. д-ры (1982), проф. (1983), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1990, 2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1962), Казан пед. ин-тында эшли, физика-матем. ф-ты деканы (1971–1972, 1978–86), теоретик физика каф. мөдире (1984 елдан). Хезмәтләре конденсацияләнгән мохитләрдә стат. физикага һәм катлаулы системалар физикасына карый. Ю. тикшеренүләре кризис һәм фаҗигаләрне алдан әйтү, төрле табигатьле физик, табигый, мед. һәм биол. системаларны анализлау һәм диагностикалау алымнарын эшләгәндә кулланыла. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2001), Татар гуманитар-пед. ун-тының шәрәфле профессоры (2010, үлгәннән соң). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О возможности сопоставления экспериментов ЯМР с данными оптической и нейтронной спектроскопии // Оптика и спектроскопия. 1973.Т.35, № 3; Описание магнитной релаксации спинов в жидкостях на основе идеи Боголюбова об иерархии времён релаксации // Теорет. и мат.физика. 1977.Т.30, № 2; Stochastic dynamics of time correlation in complex systems with discrete time // Rhys. Rev. E. 2000. V. 62.

**ЮМАГУ́ЛОВ** (Йомагылов) Илшат Хәлил улы (26.2.1932, БАССРның Мәләвез (хәзер Куергазы) р-ны Тимербай а. — 3.11.2007, Уфа ш.), драма актёры, драматург, БАССРның һәм РСФСРның атказ. артисты (1976, 1979). Уфа сәнгать уч-щесенең театр бүлеген (1952, Х.Г.Бухарский курсы) һәм Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тын (1959, О.И.Пыжова һәм Б.В.Бибиков курсы) тәмамлый. 1952–71 (бүленеп) һәм 1976–1989 елларда Башкорт акад. драма театры актёры, аның сәхнәсендә Хәйретдин («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Макбет (шул исем. әсәр буенча, У.Шекспир), Иванов (шул исем. әсәр буенча, А.П.Чехов), Никита («Караңгылык хөкем сөргәндә», Л.Н.Толстой), Акъегет («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Закир («Кара йөзләр», М.Гафури әсәре буенча), Әнвәр («Кеше бәхете», Н.Асанбаев) һ.б. рольләр башкара. 1971–76 да Казанда Татар акад. театрында, аның сәхнәсендә психол. тирәнлек б-н сугарылган тормышчан һәм сәнгатьчә эшләнгән истә калырлык образлар иҗат итә: Арсланов («Намус хөкеме», Д.Вәлиев), Исмәгыйль («Галиябану», М.Фәйзи), Тимерхан («Нәркәс», И.Юмагулов), Большов («Агай-эне — ак мыек», А.Н.Островский), Пугачёв («Бәхтияр Канкаев», Т.Миңнуллин), Рябинин («Чит кеше», И.М.Дворецкий), Саматов («Чикләвек төше», Г.Ахунов) һ.б. Башкорт һәм татар театрлары сәхнәләрендә куелган пьесалар авторы: «Нәркәс», «Торналар кайтканда», «Югалтулар аша», «Буш бишек», «Ефәк аркан», «Мәхәббәт кошлары» һ.б. 1991–2002 дә Эстәрлетамак театр берләшмәсенең Башкорт драма театрында эшли, бер үк вакытта, 1962–66 да Уфа сәнгать уч-щесендә, 1982–90 да Уфа дәүләт сәнгать ин-тында укыта. БР Театр эшлеклеләре берлеге (1953), БР Язучылар берлеге (1989) әгъзасы.

Ә с ә р.: Драмалар. Уфа, 2007.

*Әд.:* И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; ш у л у к. Театр имени Камала. К., 1986; Башкирская энциклопедия. Уфа, 2011. Т. 7. *И.И.Илялова.*

**ЮМА́ЕВ** Җамалетдин Хәлиулла улы (1892, Оренбург губ., Чиләбе өязе Эчкен волосте, Әлмән а., хәзер Курган өлкәсенең Әлмән а. – 1940), шагыйрь, дин эшлеклесе. Троицк шәһәрендә мәдрәсәдә һәм рус-татар мәктәбендә укый. 1910–17 елларда Уфада яши, «Тормыш» басмаханәсендә корректор булып эшли. 1921 дә туган авылына кире кайта, Ялан кантонының халык мәгарифе бүлегендә инспектор булып эшли, җәдиди мәктәптә укыта, авыл мәчетендә имам вазифасын башкара. 1929 дан Ташкент өлкәсенең Карасуй р-ны колхозларының берсендә хисапчы булып эшли. Беренче шигырьләрен «Шура» ж-лында, хикәяләрен, сатира язмаларын һәм фельетоннарын татар газета һәм журналларында бастыра. «Җамалетдин Юмаев шигырьләре» (1913), «Әдәби шигырьләр» (1915) җыентыклары авторы. А.С.Пушкин һәм М.Ю.Лермонтов әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Татар шигърияте: ХХ гасыр башы. К., 2004; Ислам на Урале: Энцикл. словарь. М., 2009;

**ЮМА́Т** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 24 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 25 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1565 — 67 еллардан рус чыганакларында Починок Шигалеево Сулеменево буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородское, Иматово исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, пыяла һәм мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Преображение чиркәве (1823 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1867 дә ачыла), 2 сыйныфлы кыз балалар мәктәбе (1899), китапханә-уку залы, 1 пар һәм 4 җил тегермәне, яшелчә киптерү заводы, 2 кибет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 747 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Юмат волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 160 ир-ат; 1859 да — 334, 1908 дә — 435, 1920 дә — 509, 1926 да — 581, 1949 да — 252, 1958 дә — 272, 1970 тә — 153, 1989 да — 48, 2002 дә — 43 кеше.

**ЮМАЧИ́КОВ** Мәүлекәй (1834, Тубыл губ., Ялутор өязе Ямбай Йорты а., хәзер Төмән өлкәсенең Ямбай а. – 1910, шунда ук), мәгърифәтче шагыйрь. Татар, казах һәм гарәп телләрендә яза. Чыгышы б-н Тубыл татарларыннан. 1870–80 елларда туган авылы мәдрәсәсендә укыта. «Кыйсса-и Салсал», «Фәрһад илә Ширин» (икесе дә — 1879), «Әрбет бәете» (1881), «Кыйсса-и Тәмимдар» (1894) һ.б. шигъри һәм проза әсәрләре авторы. Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастанын казах теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* И с л а м З. «Әрбет бәете» турында // Фәнни Татарстан. 2005. № 1/2.

**ЮМОР**, (ингл. humour — комизм, холык, кәеф), әдәбиятта һәм сәнгатьтә үзендә баш геройга теләктәшлекне һәм шул ук вакытта аннан көлүне берләштергән комик юнәлешнең үзенчәлекле бер төре. *Сатира* һәм *ироniядән* аермалы буларак, юмористик характердагы әсәрләрдә автор үз героен аклый. Ю. битлеге астында вакыйгаларга җитди мөнәсәбәт яшерелә. Көлү аша герой акланып кына калмый, шул ук көлү ярдәмендә аңа соклану һәм аны данлау да яшерелә, бу аны сурәтләүдә берьяклылыктан котылырга мөмкинлек бирә. Татар Ю.ы фольклорга, аерым алганда, шаян җырларга, хайваннар турындагы җырларга, мәсәлләргә барып тоташа. 20 йөз башында Ю. Г.Тукай лирикасына, Ф.Әмирхан, Г.Гобәйдуллин прозасына, К.Тинчурин («Назлы кияү»), Г.Камал («Зәңгәр шәл») һәм Ш.Камал («Хаҗи әфәнде өйләнә») комедияләренә үтеп керә. Әлеге дәвер әсәрләре өчен милли характерның үзенчәлекләрен, яшәү рәвешен, дөньяга карашны тасвирлаганда «күз яшьләре аша көлү» хас. Татар әдәбиятында Ю.ның чәчәк аткан вакыты совет чорына туры килә. Г.Афзал, З.Мансур, Ш.Галиев, Ф.Баттал, соңрак К.Кәримов, З.Хәкимнең юмористик әсәрләрендә көлүнең бөтен төрләре очрый (кайвакыт ул үткен сатирага әверелеп китә). Юморлылык һәм җитдилек Т.Миңнуллин, Р.Миңнуллин, Р.Мингалим, И.Юзеев, Ф.Яруллин һ.б. иҗатларында уңышлы ярашалар.

*Әд.:* Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007. *А.А.Шәмсутова.*

**ЮНАЛИ́ЕВА** Румия Айнетдин кызы (7.8.1930, Волгоград ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1985), проф. (1988), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). Казан ун-тын тәмамлый (1954). 1957–59, 1961–95 елларда Казан ун-тында. 1959–61, 1995–2000 дә Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1997 дән — ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты). 2003–06 да Казан пед. ун-тында. 2009 дан Чаллы пед. ин-ты профессоры. Хезмәтләре контактология, тарихи лексикология, лексикография, диалектология мәсьәләләренә,

рус телендәге төрки алынмаларга, милли аудиториядә рус теле укыту методикасына карый. Ю. — югары уку йортлары һәм урта мәктәпләр өчен рус теленнән уку ярдәмлекләре һәм программалар авторы; татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр төзүчеләрнең берсе. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Опыт исследования заимствований: Тюркизмы в русском языке сравнительно с другими славянскими языками. К., 1982; Тюркизмы русского языка (Проблемы полиаспектного исследования). К., 2000; Обучение русскому литературному произношению. К., 2003; Тюркизмы в русской классике. К., 2005; Тюркизмы в сравнительных оборотах русского языка: Словарь. К., 2011.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3; Казанская лингвистическая школа. К., 2008.

*К.Р.Галиуллин.*

**ЮНӘЛЕ́Ш**, төрле объект-субъект мөнәсәбәтләрен белдерүче фигыльләргә хас грамматик категория. Татар телендә биш юнәлеш формасы бар: 1) төп юнәлеш (бизәү), 2) төшем юнәлеше (бизә**л**ү), 3) кайтым юнәлеше (бизә**н**ү), 4) уртаклык юнәлеше (бизә**ш**ү), 5) йөкләтү юнәлеше (бизә**т**ү). Барлык юнәлеш формалары да булган фигыльләрнең саны йөздән артмый, мәс., актару, йөгерү, йөрү, казу, карау һ.б. Йөкләтү юнәлешен барлык диярлек фигыльдән дә ясарга мөмкин; төшем юнәлеше — бары тик күчемле фигыльләрдә генә һәм барлык фигыль лексикасының якынча биштән бер өлешендә, уртаклык һәм кайтым юнәлешләре өчтән бер өлешендә генә күзәтелә. Юнәлеш формалары сүз төрләнешенә һәм сүз ясалышына мөнәсәбәте булган катлаулы системаны тәшкил итә.

*Әд.:* Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; Татар грамматикасы. Морфология К., 2016. Т. 2; З и н н а т у л л и н а К.З. Залоги глагола в современном татарском литературном языке. К., 1969.

*К.З.Зиннәтуллина.*

**ЮНГЕ́РОВ** Павел Александрович (1856, Самара губ. — 1921 яки 1922, Саратов губ., Балаково ш.), Библия белгече, чиркәү тарихы д-ры (1897), Россиянең мактаулы граждани (1913). Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1879), шунда ук укыта. 1888–89 елларда Шәрекъ һәм Көнбатыш Европа илләрендә фәнни командировкада була. Хезмәтләре исагогика (дини текстларның тарихи чыганакларын өйрәнүче библеистика бүлеге), экзегетикага (Библия текстларын аңлату) карый. Иске Гаһед китабының рус теленә тәрҗемәләре авторы.

Х е з м.: Книга пророка Амоса: введение, перевод и объяснение. К., 1897; Введение в Ветхий Завет: В 2-х кн. М., 2003; Книги Ветхого Завета в переводе П.А.Юнгерова. Пророк Даниил. Малые пророки. М., 2006; Книги Ветхого Завета в переводе П.А.Юнгерова. Учительные книги. М.. 2012.

**ЮНИ́ЦКИЙ** Александр Александрович (20.3. 1878, Тула губ., Ефремов өязе Новопетровский а. — 1942), урман белгече. С.-Петербург урман ин-тын (1900) һәм Франция югары урман мәктәбен (Нанси ш., 1903) тәмамлый. Херсон һәм Воронеж губерналарында урманчы ярдәмчесе булып эшли. 1912–15 елларда һәм 1918 дә Казан тәҗрибә урманчылыгының 1 нче разрядлы урманчысы. 1916–17 дә хәрби хезмәттә. 1919–36 да (бүленеп) Казан ун-ты профессоры. Урман ф-ты деканы (1922). 1922–33 тә Казан а.х. һәм урманчылык ин-ты профессоры. 1933–35 тә Гагра тәҗрибә станциясендә. 1937 дән Бөтенсоюз урманчылык һәм урман хуҗалыгын механикалаштыру фәнни-тикшеренү ин-тының (Мәскәү өлкәсе, Пушкино ш.) Мәскәү урман хуҗалыгы фәнни-тикшеренү ин-тында фитопатология лаб-ясе башлыгы. Хезмәтләре урманчылык, урман фитопатологиясе һәм урман таксациясенә карый. Ю. яфраклы токымнарны киртләү һәм киртләү ярдәмендә продуктлар алу алымы эшли. Өй гөмбәләре б-н көрәш ысуллары тәкъдим итә. Урман үстерү эше буенча күп кенә прибор һәм инструментлар конструкцияли.

Х е з м.: К истории открытия в Казани Высшей лесной школы // Сб. науч. статей Казан. ин-та сел. хоз-ва и лесоводства. 1925. Вып. 1; Казанское Лесное общество // Изв. Казан. ин-та сел. хоз-ва и лесоводства. 1928. № 1; О значении в лесном хозяйстве грибных вредителей деревьев и необходимости планового их изучения. К., 1929.

*Әд.:* О в ч и н н и к о в А.Р. Казанский лесотехнический институт // Изв. Казан. лесотехнического ин-та. 1931. № 2/3.

**ЮНИ́ЧЕВ** Хәбиб Фазылҗан улы (10.10.1906, Кытай, Голҗа ш. — 1945, шунда ук), Кытайның сәясәт эшлеклесе. Истанбул инглиз колледжында, Истанбул ун-тының мед. ф-тында (1926–29) укый. Уйгыр «Или елгасы» («Иля дарьяси») г-тасын оештыручыларның берсе һәм аның беренче мөхәррире (1934–44). 1939 елда Ю. тәкъдиме б-н Голҗада беренче гавами китапханә оештырыла. 1940 еллар башында Шөнҗанда милли-азатлык хәрәкәтендә катнаша. 1944 тән Көнчыгыш Төркестан Халык Респ-касы халык мәгарифе министры, аның сәяси декларациясен эшләүдә катнаша.

*Әд.:* Г о с м а н о в М. Ябылмаган китап яки чәчелгән орлыклар. К., 1996; М и н в а л е е в А. Как татары помогли уйгурам // Восточный экспресс. 2004. 13 нояб.

*М.Г.Госманов.*

**ЮНЫ́С** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 14 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 57 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1565—67 еллардан рус чыганакларында Пустошь Иски Юрт исеме б-н билгеле, 17 йөз уртасына С.Т.Аристов биләмәсе була һәм авыл хәзерге исемен йөртә башлый. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ю.та чиркәү-приход мәктәбе (1887 дә ачыла), су тегермәне, ярма яргыч, 2 ашлык саклау-сату һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1136 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Сәләнгеш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 118 ир-ат; 1859 да — 423, 1897 дә — 684, 1908 дә — 573, 1920 дә — 634, 1926 да — 486, 1949 да — 248, 1958 дә — 216, 1970 тә — 126, 1979 да — 52, 1989 да — 50, 2002 дә — 68 кеше.

**ЮНЫ́С** (Юнысов) Әхмәт Юныс улы (15.10.1916, Мамадыш өязе Әсән Елга а. – 7.7.1976, Казан), шагыйрь. Совет-фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1949), «Яшь сталинчы» г-тасы, «Пионер» ж-лы редакцияләрендә, Татарстан китап нәшриятында эшли (1958 елга кадәр). «Тантана» (1939), «Әсән-елга» (1941), «Кырларга сәяхәт» (1955), «Туган җирем, сиңа җырым» (1966), «Бәхет» (1974), «Үземнең язым» (1976) шигырь җыентыклары авторы. Үзенең әсәрләрендә беренче бишьеллыкларның героикасын, совет кешеләренең хезмәттәге һәм фронттагы батырлыгын, СССР халыклары арасындагы дуслык хисләрен чагылдыра. К.И.Чуковскийның, С.Я.Маршакның, А.Л.Бартоның балалар өчен әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**ЮНЫ́С** (Юнысов) Вахит Закир улы (20.10.1930, Баулы р-ны Исергәп а. – 15.10.2006, Мәскәү, туган авылында җирләнә), язучы, публицист. Бөгелмә укытучылар ин-тын (1951), Мәскәү халыкара мөнәсәбәтләр ин-тын (1959), СССР Госпланының югары икътисад курсларын (1973) тәмамлый. Гыйрак, Мисыр, Әфганстан, Сүрия илчелекләрендә эшли. Шәрекъ илләрендә алган тәэсирләрен көндәлек дәфтәренә теркәп бара, 2000 елда бу язмалар «6000 көн чит илләрдә» исеме б-н китап булып басылып чыга. 1997 дән «Татарские новости» (Мәскәү) г-тасында баш мөхәррир урынбасары.

*Әд.:* В ә л и е в Р. Гомерлек мосафир // Казан утлары. 2000. № 10.

**ЮНЫ́С** *бине́* **ИВАНА́Й** (1639–1689/1690), дин эшлеклесе. Югары Оры авылында (хәзер Арча р-нында) имам-хатип, мөдәррис. Урта Азия мәдрәсәләренең берсендә белем ала. Замандашлары фикеренчә, 1552 елда Казан ханлыгы яуланганнан соң, мөселман татарлар арасыннан беренче булып хаҗ сәфәре кылган. Берничә уку ярдәмлеге авторы.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Асар. К., 2010. Т. 1.

**ЮНЫ́С МӘЧЕТЕ́**, к. *Мәрҗани мәчете*.

**ЮНЫ́С** (Юнысов) Миргазиян Закир улы (25.5.1927, Баулы р-ны Исергәп а. — 2.6.2014, Мәскәү, туган авылында җирләнә), язучы, диңгезче. Татар һәм рус телләрендә яза. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1961). 1944–55 елларда СССР Хәрби Һава көчләрендә хәрби очучы, 1957–68 дә Кара диңгез пароходчылыгы сәүдә корабльндә капитан ярдәмчесе булып хезмәт итә. 1968–72 дә СССР Диңгез флоты министрлыгында, аннары, 1973 тән, «Наука и религия» ж-лы редакциясендә бүлек мөдире вазифаларын башкара. 1977–87 дә Азов диңгез пароходчылыгы корабльләрендә хезмәт итә. Матбугатта әсәрләрен 1960 елларда бастыра башлый. Язучының диңгезчеләр тормышы һәм хезмәте, ерактагы диңгезләр һәм илләр турындагы хикәяләре укучылар игътибарын җәлеп итә: «Тимер фил» (1968), «Занзибар зәңгәр болытлар артында» (1970) җыентыклары. «Тозлы җил» (1973), «Теләп алынган давыл» (1975), «Таңда Босфор аша» (1984) повестьлары «Дөнья

гизү» трилогиясен (1987; русчага тәрҗемәсе «Наука странствий», 1997) тәшкил итә. Ю. — татар әдәбиятында беренче маринист. Аның әсәрләрендә диңгез темасы әхлакый мәсьәләләр, туган җир, татар халкының үткәне, хәзергесе һәм киләчәге турында уйланулар б-н тыгыз үрелеп бара.



М.З. Юныс.

«Табу һәм югалту» (1978), «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» (1979), «Юлларда уйланулар» (1990) повестьлары татар прозасының геогр. горизонтларын киңәйтәләр, аны яшәүнең мәгънәсе, кешенең үз намусы алдында җавап тотуы турындагы фәлсәфи уйланулар б-н баеталар. Вакытлы матбугатта татар халкының мәдәнияте, теле, милли үзаңы турындагы публицистик мәкаләләрен бастыра. «Альбатрос язмышы» (2002) публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы авторы. Әсәрләре рус, инглиз телләренә тәрҗемә ителә. Ю. агачка уеп бизәк төшерү, скульптура б-н шөгыльләнә. Аның эшләреннән торган күргәзмә «Казан» милли мәдәният үзәгендә уза (1995). Әсәрләре заманча сәнгать музеенда (Испания, Барселона ш.), РФ, ТРда шәхси коллекцияләрдә саклана. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты.

Ә с ә р.: Әсәрләр. К., 2005; Әсәрләр: 6 томда. К., 2005–07.

*Әд.:* М и ң н у л л и н Ф. Биектә калу // Балта явызлар кулында. К., 1994; Р а х м а н и Р. Кыйблага тугрылык // Казан утлары. 2002. № 4.

**ЮНЫ́С** (Юнысов), Рәфикъ Юныс улы (1.3.1943, Арча р-ны Кәче а.), шагыйрь, публицист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1993). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), «Татарстан яшьләре» г-тасы редакциясендә, Татарстан китап нәшриятында (1985–91, 1989 елдан баш мөхәррир урынбасары), «Идел» ж-лы редакциясендә (1992–2004) эшли, 2005–18 дә «Казан утлары» ж-лы баш мөхәррире урынбасары, бүлек мөдире. «Вакыт чылбыры» (1982), «Җирдә яшим» (1986), «Учтагы песнәк» (1989), «Сүнгән яшен» (1991), «Син һәм мин» (1993) шигырь җыентыклары, «Татарстан референдумы» (2000) тарихи хроникасы авторы. Әсәрләрендә Ю. кискен иҗтимагый-сәяси, милли, әдәп-әхлак, культурология мәсьәләләрен күтәрә. Татар әдәбиятының «Казан утлары» ж-лында басылып чыккан аеруча танылган әсәрләреннән «Сүнмәс утлар балкышы» (2006) антологиясен төзи. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге лауреаты (2004).

*Әд.:* Г ы й л ь м а н о в Г. Сискәндерә торган шигырьләр // Казан утлары. 1990. № 3; Г а л и е в а Г. Халкым дип яши // Күңелемә якын затлар. К., 2007.

**ЮНЫ́СОВ** Борис Николаевич (Нәбиулла Зәйнулла улы) (12.12.1925, Ленинград – 3.4.1980, Ульянов өлкәсенең Димитровград ш.), Сов. Союзы Герое (21.7.1944), гв. өлкән сержанты. Юридик мәктәп тәмамлый (Куйбышев ш., 1952). Мәләкәс (хәзер Димитровград) чуен-металл кою з-дында эшли. 1943 елның февраленнән Кызыл Армиядә. 1944 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 300 нче гв. укчы полкының (7 нче армиянең 99 нчы гв. укчы дивизиясе) укчы-разведчигы. Карелия фронты гаскәрләре составында Свирица-Петрозаводск һөҗүм операциясендә катнаша (1944). 1944 нең 21 июнендә Свирь елгасын кичкәндә һәм төньяк ярда плацдарм булдыруда батырлык күрсәтә: полкның 12 сугышчысы төркемендә, дошманның яшерен ут җайланмаларын ачыклау максаты б-н елга аша разведка яшерен кичүендә катнаша. Төркем дошман оборонасының эченә үтеп керә һәм төп көчләргә елганы кичеп чыгарга ярдәм итә. 1950 елларга кадәр һава десанты гаскәрләрендә хезмәт итә. 1952–58 дә Куйбышев шәһәрендә халык судьясы, 1959 дан Димитровград төзелеш идарәсендә бизәүче рәссам булып эшли. Димитровград шәһәрендәге Дан аллеясында Геройның бюсты урнаштырылган. Ю. яшәгән йортка, ул эшләгән «Химмаш» з-ды бинасына мәрмәр такталар куелган. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Б.Н. Юнысов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЮНЫ́СОВ ЙОРТЫ́**, к. *Апанаев йорты.*

**ЮНЫ́СОВ** Мөхәммәдзариф (якынча 1850, хәзерге Түбән Новгород өлкәсе Кызыл Октябрь р-ны Куйсуы а. — 22.11.1914, Петербург ш.), дин эшлеклесе. Казандагы Апанай мәдрәсәсен һәм Бохара шәһәрендә мәдрәсә тәмамлаганнан соң, 1874 елдан башлап С.-Петербург шәһәрендәге 1 нче мәхәлләдә имам, мөдәррис, ахун ярдәмчесе, 1888 дән шул ук мәхәлләдә имам-хатип. 1913 тән Петербургтагы җамигъ мәчетнең имам-хатыйбы. Хәйрияче буларак та билгеле.

*Әд.:* З а г и д у л л и н И.К. Мусульманская община в Санкт-Петербурге. XVIII — начало XX вв. К., 2003; Т е л я ш о в Р. Татарская община Санкт-Петербурга: К 300-летию города. СПб., 2003; Ислам в Санкт-Петербурге: Энцикл. словарь. М., 2009.

**ЮНЫ́СОВ** Рәүф Әдһәм улы (2.5.1947, Чистай р-ны Үтәш а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2002), проф. (2004), ТАССРның атказ. агрономы (1983). Минзәлә а.х. техникумын (1967), Казан а.х. ин-тын (1974) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1967 елда Чистай р-нының «Буревестник» с-зында вет. табибе булып башлый.1974–75 тә, 2002–05 тә Казан аграр ун-тында: укыту-тәҗрибә хуҗалыгында баш агроном, җиләк-җимеш-яшелчәчелек каф. мөдире (2002 дән), бер үк вакытта проректор (2003 тән). 1975–85 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында, 1986–88 дә ТАССРның Дәүләт агросәнәгать ком-тында бүлек башлыгы, 1988–2002 дә «Татсемсвёкла» ДУП ген. директоры. 2006 дан Россельхознадзорның ТР буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары. 2009 дан Социаль һәм гуманитар белемнәр ин-тының дәүләт һәм муниципаль идарә каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләре шикәр чөгендере продуктлылыгының селекцион-генетик потенциалын һәм РФнең чөгендер чәчә торган төньяк районнарында сәнәгый максатларда чөгендер игүнең нәтиҗәлелеген өйрәнүгә, орлыкларны чәчүгә әзерләүнең сәнәгый технологияләрен эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә багышлана. Ю. — Россия технологиясе буенча эшли торган беренче орлык з-ды проекты авторы. Уйлап табуга 13 патенты бар, уйлап табучыларның респ-ка бәйгеләрендә җиңүче (2000, 2001, 2004). Күп максатларда кулланыла торган хелат комплекслы микроашламаларны эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен ТР Дәүләт бүләге бирелә (2000). Медальләр, ш.и. Бөтенроссия күргәзмәләр үзәгенең көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Агротехника одноростковой кормовой свёклы на семена. К., 1992; Северное свеклосеменоводство. К., 1998; Сахарная свёкла в лесостепи Поволжья. К., 2002; Биоэкология размножения и адаптивные технологии в селекции и семеноводстве свёклы. К., 2004.

*Әд.:* Ж а р к о в а В. Семеноводство — престижная отрасль // Сахарная свёкла. 1999. № 9; Кто есть кто: Республика Татарстан. К., 2002.

**ЮНЫ́СОВ** Фәйзрахман Сәлах улы (14.9.1924, Кама Тамагы р-ны Атабай а. — 6.4.2012, Казан), авиация технологияләре өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1969), проф. (1971), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1987), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2007), РСФСРның, СССРның атказ. уйлап табучысы (1985, 1991), Казан техник ун-тының атказ. профессоры (1997), ТР ФАнең шәрәфле академигы. (2010). 1953 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, очкыч аппарат моторларын җитештерү каф. мөдире (1973–89), каф. профессоры (1990 нан). Детальләрнең катлаулы профильле өслекләрен формалаштыру буенча фәнни юнәлешкә нигез сала. Ю. технол. параметрларны хисаплау алымнарын һәм алгоритмнарын эшли; детальләр җитештерү процессын механикалаштыру һәм автоматлаштыру чараларын булдыра, бу очкыч аппарат двигательләренең, вертолётларның корыч калакларының ресурсын һәм ышанычлылыгын арттырырга, авиация двигательләрен эшләп чыгару срокларын кыскартырга мөмкинлек бирә. «Катлаулы профильле өслекләрне механик эшкәртү юлы б-н формалаштыру» («Формообразование сложнопрофильных поверхностей механообработкой») хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1995). Авиация тармагы инженер-техник хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү ф-тын оештыра, ун-т студентларын индивидуаль әзерләү максатчан программасын булдыруны башлап йөри. Уйлап табуга 100 дән артык авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. «Прогрессивные методы обработки деталей летательных аппаратов и двигателей» вузара җыентыгының җаваплы мөхәррире (1971–95). Бөек Ватан сугышында катнаша. Өч Ватан сугышы (берсе 1 нче дәрәҗә, икесе 2 нче дәрәҗә), ике Кызыл Йол-



Ф.С. Юнысов.

дыз, Халыклар Дуслыгы, 3 нче дәрәҗә Дан, Почёт билгесе орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре, «Югары технологияләрне үстерүдә күренекле хезмәтләре өчен» Бөек Пётр медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Формообразование сложнопрофильных поверхностей шлифованием. М., 1987; Размерное и безразмерное формообразование поверхностей деталей. М., 1996 (автордаш); Формирование информационно-поисковой системы инструментального обеспечения автоматизированного производства и проектирование САПР РИ. М., 2000 (автордаш).

*Әд.:* Современный интеллектуальный потенциал России. М., 1997. Т. 1.

**ЮНЫ́СОВА** Сәйяр Сәгыйрь кызы (31.7.1927, Казан — 27.4.2008, шунда ук), балет артисты, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989). 1945 елда Мәскәү акад. хореография уч-щесен (педагог М.Леонтьева), 1951 дә Ленинград консерваториясенең педагог-хореографлар бүлеген тәмамлый. 1951–61 дә Татар опера һәм балет театры солисты. 1961–62 дә Пермь, 1962–71 дә Новосибирск хореография уч-щеләрендә педагог. 1971–74 тә Татар опера һәм балет театры педагог-репетиторы, бер үк вакытта, 1972–85 тә, Казан музыка уч-щесендә хореография бүлеге җитәкчесе һәм педагог, 1992–2006 да Казан хореография уч-щесендә методик кабинет җитәкчесе. Татарстанда проф. хореография белеме бирүне үстерү эшендә актив катнаша. Ю. укучылары арасында РСФСРның халык артисты Л.Матюхина-Василевская, РСФСРның атказ. артисты Е.Брижинская, Л.Попилина, К.Иванов, Н.Шильников, Л.*Мөхәмммәтгалиева* һ.б. бар.

*В.Н.Горшков.*

**ЮНЫ́СОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре, җәмәгать эшлеклеләре, Казанның иң бай сәүдәгәрләр династияләренең берсе. 1) **Мөхәммәдрәхим Исхак улы** (1743, Кариле а., хәзер Балтач р-ны — 1820), сәүдәгәрләр династиясенә нигез салучы, Казанда күн з-ды хуҗасы (1818 елда завод 13 мең данә тире эшкәртә). Түбән Новгород, Оренбург, Эрбет ярминкәләрендә, Урта Азиядә күн товарлар б-н сату итә. 1793 тә Татар ратушасы шәһәр башлыгы. 2) **Габделкәрим Мөхәммәдрәхим улы** (1767, Казан — 1825), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре. 1818 дә ике катлы таш йорт (32 мең сумга бәяләнә) һәм Печән базары мәйданында 20 вак кибет, Гостиный дворда — 20, Икмәк базарында — 2 кибет, Пләтәндә — сабын кайнату з-ды (1 елга 10 мең пот сабын һәм шәм җитештерә) били; **Гобәйдулла Мөхәммәдрәхим улы** (1776, Казан — 13.12.1842, шунда ук), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, нәселдән күчмә мактаулы граждан. Сабын кайнату һәм 2 күн з-ды хуҗасы. Товарларын Кытайга алып барып сата. Иң бай татар эшмәкәрләренең берсе: 1830 еллар ахырында аның капиталы 3 млн. сумнан артып китә. Зиннәтле аерым йортта яши. Аның утары каршындагы мәйдан Юнысов мәйданы дип йөртелә башлый. Басмаханә хуҗасы, нашир; аның басмаханәсендә нәшер ителгән дини һәм дәрес китапларының бер өлеше мөселманнарга бушлай таратыла. 1842 дә Татар ратушасы шәһәр башлыгы. Юмарт иганәче: аның акчасына берничә авыл мәчете төзелә, 1849 да Казанда Печән базары мәчете (Юнысовлар мәчете дип атала) корыла. 1 нче җамигъ мәчетне (хәзер Мәрҗани мәчете) карап тотуга зур күләмдә акчалар сарыф итә: 1837 дә мәчет каршында мәдрәсә өчен ярым таш бина салдыра; 1830 да Печән базары мәйданындагы кибетләрен мәчет карамагына тапшыра, алардан килгән табыш имамнар һәм мөәзиннәрне



Юнысовлар гаиләсе. 20 йөз башы фоторәсеме.

тәэмин итүгә китә. 1830 да, Казанда холера (ваба) эпидемиясе вакытында, татар сәүдәгәрләре б-н берлектә хастаханә төзелешенә акча бүлеп бирә. Ике алтын медаль б-н бүләкләнә; **Габдерәшит Мөхәммәдрәхим улы** (?–?), 3 нче гильдия Казан сәүдәгәре. 1818 дә Екатерининский урамында йорт, Печән базары мәйданында кибетләр, Зур Мещан урамында күн з-ды били. К.Ф.Фукс мәгълүматлары буенча, 1830 еллар ахырына аның мөлкәте 2 млн. сум тәшкил итә. 3) Бертуганнар **Ибраһим Гобәйдулла улы** (1806, Казан — 4.4.1886, шунда ук) һәм **Исхак Гобәйдулла улы** (1810, Казан — 24.3.1884), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәрләре, нәселдән күчмә мактаулы граждannar, коммерция советниклары (әлеге югары исемгә лаек булган бердәнбер татар эшмәкәрләре). Казандагы сабын кайнату һәм туңмай-шәм з-длары, Казан губернасы Казан өязендә кәҗүл һәм күн з-длары, Уржум шәһәрендә киҗе-мамык эрләү ф-касы, Вятка губернасы Уржум өязендә язу һәм төрү кәгазе ф-касы хуҗалары. С.-Петербургта, Мәскәүдә, Әстерханда, Оренбургта, Кяхтада, Бохарада, Ташкентта, Персиядә сәүдәгәрлек итәләр. Капиталның сәүдә әйләнеше 1,5 млн. сум көмеш тәшкил итә. Аларның 5 таш йорты, Казанда 48 таш һәм 12 агач кибете, Казан һәм Вятка губерналарында 2 мең дисәтинәдән артык җирләре була. 1844, 1845, 1854 тә Ибраһим Ю. — Татар ратушасы ратманы (шәһәр башлыгы), 1871–86 да Казан шәһәр думасы гласные була, 3 нче дәрәҗә Изге Анна ордены, ике алтын медаль б-н бүләкләнә. 1863 тә Казанга сәфәре вакытында аның йортында цесаревич, бөек кенәз Николай Александрович булып китә. Ибраһим һәм Исхак Ю. *Мөселман балалар ятимханәсен* (1844) нигезлиләр һәм тәэмин итеп торалар. Ятимханәгә 14 вак кибет иганә итәләр, алардан килгән табыш ятим балаларны карауга тотыла. Исхак Ю. — 1844 тә ятимханә химаячесе, 1859 да директоры вазифасында раслана. Хәйрия эшчәнлеге өчен 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. 1884 тә мөселман гарипләр йорты өчен бертуганнар ике катлы таш йорт һәм Печән базарында 2 таш кибет иганә кылалар. 4) **Габделкәрим Исхак улы** (5.1.1853–1928), 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре, нәселдән күчмә мактаулы граждан. Каһирәдә «әл-Әзһәр» ун-тын тәмамлый. 1875 тә Оренбург Мөселман Диния нәзарәтендә Казан губернасы мәхәлләләренең берсендә имам-хатип вазифаларын башкару хокукына имтихан тота, әмма 1880 дә аңа коммерция эшчәнлегенә күчәргә туры килә. Кыйммәтле мех товарлар б-н сәүдә итә. 1899 да аның акчасына Казан губернасы Мамадыш өязе Кәчимир авылында мәчет салына. 1887 дә Казанда Мөселман хәйрия җәмгыятенә ике катлы кирпеч йортны файдалануга тапшыра. Окт. рев-циясе башыннан (1917–18 дә) Ю. эшмәкәрлек эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр булалар.

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1994; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998; Д е в я т ы х Л.И. Люди и судьбы. К., 2003.

*Р.Р.Салихов, Л.М.Свердлова.*

**ЮНЫ́СОВЛАР БАЛАЛА́Р ЯТИМХАНӘСЕ́**, к. *Мөселман балалар ятимханәсе.*

**ЮНЫ́СОВЛАР МӘЙДАНЫ́** Казанда, *Иске Татар бистәсендә*. 1768 елда шәһәрнең В.И.*Кафтырев* тарафыннан эшләнгән беренче регуляр планы нигезендә 18 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килә. Сәүдәгәр һәм фабрикант *Юнысовлар* хөрмәтенә атала. Екатерининский (хәзерге Г.Тукай ур.) һәм 2 нче Аркылы урам (хәзерге Ф.Кәрим ур.) чатында урнаша. 19 йөз урталарына кадәр мәйдан тирәли классицизм стилендәге агач йортлар һәм утарлар корыла. Ике катлы беренче таш йорт 19 йөз башында сәүдәгәр Мөхәммәдрәхим Юнысов тарафыннан төзелә. 19 йөз ахырына андагы бик күп йорт-каралтылар Юнысовлар нәселе милке була. Ю.м.ндагы йортларның барысы да 1840 елларның үрнәк проектлары буенча эшләнә, мәйдан бер стильдәге архит-ра ансамбле кыяфәтен ала. 19 йөзнең 2 нче яртысында анда төрле юнәлештәге эклектика стилендәге йортлар һәм утарлар барлыкка килә. 19 йөз ахырында Ю.м.ндагы Мөстәкыймовлар йорты флигелендә «Халидия» мәдрәсәсе, элек сәүдәгәр Апаковларныкы булган йортта татар укытучылар мәктәбе эшли. Мәйданның почмак өлешләрен бакчалар алып тора. Шушы ук чорда Юнысовларның элекке йорты М.Апанаев өчен модерн стилендә үзгәртеп корыла. Мәйданга караган флигельдә аның сәүдә фирмасы конторасы урнаша. 20 йөз башында Ю.м. ансамбленә *Шамил йорты, Апанаевлар йорты, Бәхтиев йорты* һ.б. биналар керә.

1913 елның апрелендә Ю.м.нда Г.Тукай б-н хушлашу мәрәсиме үткәрелә. 1920 елларда калын постаментта М.*Вахитов* бюсты

урнаштырыла һәм мәйдан аның исеменә үзгәртелә. 1960–70 елларда Ю.м.ның төньяк-көнбатыш һәм төньяк-көнчыгыш өлешләрендәге бер катлы йортлар сүтелә, алар урынына мәйданның архит-ра бөтенлеген боза торган Г.Тукай исем. кинотеатр һәм биш катлы кирпеч йорт төзелә. 1986 да Г.Тукай исем. мәйдан итеп үзгәртелә, 1997 дә тарихи Юнысовлар исеме кире кайтарыла. 1990 елларда андагы бер, ике катлы йортлар өлешчә сүтелә. 2000 елларда Г.Тукай исем. кинотеатр юк ителә, аз катлы сәүдә-офис комплексы





Юнысовлар мәйданы. 1. Казан. 1920 еллар фотосы; 2. Хәзерге күренеше.

һәм элитар класслы зур торак бина корыла. Ю.м.ның көньяк-көнбатыш өлешендә Шамил йортына якын һәм көньяк-көнчыгыш өлешендә Укытучылар мәктәбе алдындагы терр-я аз катлы офис биналары төзү өчен бирелә.

*Әд.:* Н у г м а н о в а Г.Г. Прогулки по Старотатарской слободе // Казанское время. 1998. 29 июля; А м и р о в К.Ф., Ахметзянова Р.Х., Вениаминов Р.Г. Казанских улиц имена. К., 2008.

*Г.Г.Ногманова.*

**ЮРА́ СИСТЕ́МАСЫ (ЧОРЫ́)**, ю р а, мезозойның икенче системасы, акбур чоры алдыннан барлыкка килгән. 167,7±3,5 млн. ел элек башланган, 145,5±4 млн. ел элек тәмамланган. Өч бүлеккә бүленә. ТР терр-ясендә урта (югары горизонтлар) һәм югары бүлекләре бар, респ-каның көньяк-көнбатышында җәелгән. Калынлыгы 100 *м* чамасы. Диңгез һәм континент шартларында балчык, мергель, глауконитлы конгломератлар утырмалары барлыкка килгән. Токымнарда диңгез организмнары, кәлтәләр, моллюсклар, фораминифера, акула тешләре калдыклары, абагасыманнарның, ылыслыларның споралары һәм серкәләре табыла. Балчык, фосфорит, янучан сланецлар чыганаклары бар.

**ЮРА́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Туйма елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 31,4 *км*, ТР чикләрендә — 24 *км*. Бассейнының мәйданы 203 *км*². Можга калкулыгыннан ага. Югары һәм түбән агымнары ТРның Менделеев р-нында, урта агымы — Удмурт Респ-касы терр-ясендә. Елга башы Бөрешле авылыннан 3 *м* төньяктарак, тамагы Менделеев шәһәреннән 3 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 71 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Ю.ның 0,6 дан 9,2 *км* га кадәр озынлыктагы 11 кушылдыгы бар, аеруча зурысы — Мактумер елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,33 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 143 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 117 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренчеункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,18 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЮРА́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Әдәм елгасының (Үмәк, Вятка елгалары бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 21,5 *км*, ТР чикләрендә — 18,5 *км*. Бассейнының мәйданы 156,4 *км*². Можга калкулыгыннан ага. Елга башы Алабуга р-ны Көек авылы читендә, түбән агымы һәм тамагы Удмурт Респ-касы терр-ясендә. Елга үз юлында өч тапкыр Татарстан һәм Удмурт Респ-касы терр-яләрен кисеп чыга. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 73 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Ю.ның 1,2 дән 9,9 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар, аеруча зурысы — Юраш елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 102 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,12 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЮРА́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Юраш елгасының (Үмәк, Вятка елгалары бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 9,9 *км*, ТР чикләрендә — 6 *км*. Бассейнының мәйданы 53,6 *км*². Можга калкулыгыннан ага. Югары һәм түбән агымы ТРның Алабуга р-ны терр-ясендә, урта агымы — Удмурт Респ-касы терр-ясендә. Елга башы Көек авылы һәм Малореченский посёлогы ягыннан Удмурт Респ-касы ягына алып баручы автомобиль юллары кушылган җирдән 2 *км* төньяк-көнбатыштарак; тамагы Сосновый Юраш авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 91 *м*. Су җыелу мәйданында урман үсемлекләре юк. Ю.ның 0,8 дән 4,7 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,5 *км/км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 104 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,045 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЮРГА́ РАЙОНЫ́**, *Кемерово өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1924 елның 24 февралендә оештырыла. Мәйданы — 2520 *км*². Үзәге — Юрга шәһәре (Кемероводан 110 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 21674 кеше (2017). 2002 елгы халык исәбе буенча, районда 1084 татар исәпләнә; тупланып Кышлау (Зимник), Сарсаз, Олы Ылыс авылларында яшиләр. Моннан тыш 2315 татар район үзәгендә (Ю.р. составына керми) яши. Район терр-ясенә элек-электән төрки телле кабиләләр килеп утыра. 17 йөздә калмаклар (телеутларның бер тармагы) килеп урнаша, алар элеккеге күчеп йөрү туктаулыкларында берничә авылны, ш.и. Кышлау, Усть-Искитим (хәзерге Юрга шәһәре читендә) h.б.ны нигезли. 19 йөзнең 2 нче яртысында калмаклар авылларына Урта Идел һәм Урал буе халыклары урнаша башлый. 20 йөз башында Кышлауга Телеут волосте әҗнәбиләре килеп утыра, мәктәпле мәчет эшли, Олы Ылыс авылында да мәчет була. 1908–09 да Уфа губернасыннан күчеп килүчеләр Сарсаз авылына нигез сала. 1926 да Кышлау авылында башлангыч мәктәп (1936 дан — җидееллык) ачыла, 1956 га кадәр укыту татар телендә (1992 дән — факультатив дәрес буларак) алып барыла. Район үзәгендә «Юрга шәһәре татар милли үзәге» иҗтимагый оешмасы (2006 дан), «Дуслык» халык ансамбле эшли. Кышлау авылында Олимпия уеннарының (1956 ел) авыр атлетика төрендә көмеш медаль яулаган Р.Н.*Хәбетдинов* туган.

**ЮРИ́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Чаж елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 34 *км*, ТР чикләрендә — 11 *км*. Бассейнының мәйданы 225,4 *км*². Можга калкулыгыннан ага. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, урман массивында, тамагы Әгерҗе р-ны Тирсә авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 77 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. Ю. елгасының 0,3 тән 8,6 *км* га кадәр озынлыктагы 20 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җә-

ен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 103 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче унконлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,18 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**«Ю́РОЧКА ЧОКЫРЫ́»**, к. *Казанка ботаника тыюлыгы.*

**Ю́РТА** (йорт сүзеннән), күчмә һәм ярымкүчмә халыкларның сүтеп-җыеп күчереп йөртелә торган торагы, тирмә. Аның нигезен киез япма б-н каплаган агач киергеләр тәшкил итә. Ул борынгы болгарлар Хәзәр иленнән Идел-Чулман буйларына күченгән вакытта файдаланыла. Ю.ның, сезонлы торак сыйфатында, Идел буе Болгар дәүләтендә һәм Алтын Урдада сакланганлыгы фаразлана. Рус елъязмалары һәм башка чыганаклардан күренгәнчә, Казанда яшәүчеләр бәйрәм вакытларында Хан болынына (Болак ермагы аръягында) Ю. лар һәм чатырлар корганнар. Идел-Чулман буенда яшәүче халыкларда Ю.ның гөмбәз формасы һәм киергеләренең урнаштырылу тәртибе б-н монголларныкыннан үзгә төрки тибы гамәлдә булган.

*Әд.:* Халитов Н.Х. Типология мобильных сооружений кочевого стиля в архитектуре Поволжья по мусульманским миниатюрам XV – XVII вв. // Науч. Татарстан. 2011. № 2.

**ЮРТА́ЕВ** Александр Николаевич (15.12.1951, Псков өлкәсе Остров ш. – 5.8.2013, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2009). 1974 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, «Татнефть» ҖБдә инженер, социол. бүлеге башлыгы булып эшли. 1987–90 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, 1990–92 дә Казан ун-тының социол., сәясәт һәм идарә секторы хезмәткәре, 1992–96 да «Такәс-Интер» АҖнең Халыкара һәм мәдәни хезмәттәшлек ассоциациясе башкарма директоры, 1996–98 дә «Кинәш» г-тасы мөхәррире. 1998–2011 дә ТР МК аппаратының, 2011–12 дә ТР Президентының мәгълүмат-аналитика идарәсе җитәкчесе. 2012–13 тә «Челтәрле компания» ген. директоры урынбасары. Хезмәтләре дәүләт идарәсе өлкәсендә инновацион технологияләр эшләүгә карый. Ю. җитәкчелегендә дәүләт оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм мәгълүматлаштыруны үстерүгә юнәлтелгән «Татарстан Республикасы электрон хөкүмәте» проекты гамәлгә кертелә.

Хезм.: Электронное правительство: концептуальные подходы к построению. К., 2007; Инновационные аспекты управления процессами создания, функционирования и развития «электронного правительства» // Государственная служба. 2009. № 3; Инновационные технологии в государственном управлении. К., 2009.

**ЮРТА́У** (Елхово) посёлогы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан – Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 390 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар – 53%, руслар – 44%) яши. Халкының төп шөгыле – мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1963 тә нигез салына, беренче исеме – Елховка, 1988 дән хәзерге атамасын (бетерелгән Юртово авылы исеменнән алынган, Түбән Кама сусаклагычы төзелгән чорда бу авыл халкы Елховка авылына күчерелә) йөртә. Халык саны: 1989 да – 334, 2002 дә – 395 кеше.

**ЮРТЫ́Ш** посёлогы, Биектау р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 36 *км* төньяктарак, Питиал елгасы буенда. 2010 елда 414 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле – мөгезле эре терлек асрау. Клуб, китапханә. 1602–03 тән Ертуш исеме б-н билгеле. 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта сугу, он тарту, слесарьлык эше, итек тегү, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет (1861 еллар тирәсе, 1897 – 98), мәдрәсә һәм мәктәп, 4 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, шырпы ф-касы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1837,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан – Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән – Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә – 242 ир-ат; 1859 да – 1071, 1897 дә – 1159, 1908 дә – 1238, 1920 дә – 1305, 1926 да – 1318, 1938 дә – 1141, 1949 да – 941, 1958 дә – 756, 1970 тә – 626, 1989 да – 467, 2002 дә – 411 кеше.

**Ю́РЧЕНКО** Галина Юрьевна (22.9.1957, Казан), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2007). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1981), Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) труппасына кабул ителә. Травести актриса буларак, нигездә, яшүсмерләр рольләрен башкара: Мальчиш («Мальчиш-Кибальчиш вакыйгасы», В.К.Железников; А.П.Гайдар хикәяләре буенча), Оля («Ямансулама, Шишок, мин кайтырмын», А.Л.Александров), Катя Каширина («Алёша Пешков», И.А.Груздев, О.Д.Форш), Лена



Г.Ю. Юрченко Мальчиш ролендә (үзәктә; «Мальчиш-Кибальчиш вакыйгасы», А.П.Гайдар хикәяләре буенча; Мальчишлар – А.Яшкин, А.Быренков).

Бессольцева («Бойкот», В.К.Железников), Катька («Сычиха», Н.Глазова), Бәләкәч («Таумата айсбергы», Д.Данилов; абыйлы-энеле Стругацкийларның «Бәләкәч» («Малыш») повесте буенча), Буратино («Юләрләр илендә Буратино маҗаралары», А.Н.Толстой повесте буенча), Оскар («Оскар һәм «алсу дөнья» тудыручы ханым», Э.-Э.Шмитт) һ.б. Актриса һәр образның үзенә генә хас холык үзенчәлекләрен, яшүсмерләрнең рухи дөньясын тирәнтен ачарга тырыша. Ю. ш.у. Малпочка («Җимерү», Б.Л.Васильевның «Кич тә булды, иртә дә» повесте буенча), Улита («Урман», А.Н.Островский), Чикита («Капитан Фракасс», Т.Готье романы буенча), Анна («Золушка», Е.Л.Шварц), Лидия Фёдоровна («Кешеләрнең яратуы», Д.Богославский; «Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге, 2015) кебек характерлы рольләр дә башкара. ТР Театр эшлеклеләре берлеге идарәсе әгъзасы.



Г.Ю. Юрченко.

**Ю́РЬЕВ МӘГАРӘСЕ́**, геол. табигать истәлеге. Идел елгасының уңъяк ярында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 4,5 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 1986 елда билгеләнә. Ландшафт комплексының мәйданы 50 *га*. Мәгарә Пермь системасының югары Казан асъярусы утырмаларында гипс б-н «опока» серияле доломит түбәләренең үзара бәйләнеше, гипсларның селтесезләнүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Җир асты коридорлары (3) системасыннан, зал (2), куыш (3) һәм юллардан тора. Гомуми озынлыгы 410 *м*. Иң зур зал – «Гипс» залы (озынлыгы 27 *м*, киңлеге 13 *м*, биеклеге 4 *м*), ориентир – төньяктан көньякка таба. «Арена» залы түгәрәк формада (диаметры якынча 9 *м*, биеклеге 6 *м*). «Яңгыр куышы» (тыкрыклар б-н озын-



Юрьев мәгарәсе. Боз сталактитлары булган карст коесы.

лыгы 30 *м*, киңлеге 1,5–2 *м*, биеклеге 12 *м*, мәгарә эчендәге макс. биеклек) су тамчыларының күплеге б-н аерылып тора. Мәгарә эчендә — йомык гипс коелары һәм гаҗәеп формалы әверелмәләр, саркыма капламнар, сталактитлар, гелектитлар, пәрдәләр рәвешендәге кальцит ясалмалары. Тирәнлеге (биеклеге) 4 *м* һәм диаметры 0,5 *м* булган «орган торбалары», минераллардан — ангидрит, мәрмәр ониксы, халцедон һ.б. очрый. А.В.Ступишин, Н.Н.Лаптева, М.С.Кавиев һ.б. тарафыннан өйрәнелә.

*Әд.:* Ишмуратов Р.Р., Лаптева Н.Н., Ступишин А.В. Юрьевская пещера // Экзогенные процессы в Среднем Поволжье. К., 1972.

*Ф.Г.Борһанов.*

**ЮСИ́ПОВ** Шамил Сафа улы (11.8.1932, Түбән Новгород төбәгенең Сергач р-ны Камка а. — 18.8.2000, Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны Чүмбәли а.), а.х. җитештерүен оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1973). Арзамас а.х.н электрлаштыру һәм механикалаштыру техникумын тәмамлый (1958). Хезмәт эшчәнлеген 1948 елда Зур Рбишча МТСда тракторчы булып башлый; 1958–90 да Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны «Чүмбәли» к-зында: механик, трактор бригадасы бригадиры, рәис (1968 дән). 1990–96 да Кызыл Октябрь р-нының социаль яклау ком-ты рәисе (Уразавыл а.). Артта калган колхоз Ю. җитәкчелегендә яхшы матди-техник базасы, квалификацияле кадрлары булган, өлкәдә а.х. продукциясен җитештерүдә алдынгы пр-тиегә әверелә. 640 укучыга исәпләнгән урта мәктәп, балалар бакчасы төзелә һәм колхоз акчасына тотыла; юлларга асфальт салына; колхозчыларга йорт төзүдә ярдәм күрсәтелә. Герой исеме җитештерү эшчәнлегендә ирешелгән зур казанышлары өчен бирелә. 1967–71 дә РСФСР ЮС, 1977–89 да Горький өлкә советы депутаты. Ике Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә. КПССның 25 нче съезды (1976), Бөтенсоюз колхозчылар съезды (1988) делегаты. Чүмбәли авылында бер урам Ю. исеме б-н атала.

*Әд.:* Нижегородские татары: Биогр. словарь — Нижгар татарлары: Биографик сүзлек. Н.Новгород, 2008. Т. 1.

*М.Ж.Гаитов.*

**ЮСУ́ПОВ** Гайса Нигъмәтулла улы (21.3.1925, Бөгелмә кантоны, хәзер Ютазы р-ны Иске Урыссу а. — 20.12.1993, шунда ук), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССР, РСФСРның атказ. агрономы (1975,1980). Бөек Ватан сугышында катнаша. Колхоз рәисләрен әзерләү буенча Татарстан урта а.х. мәктәбен (1955), Казан а.х. ин-тын (1961) тәмамлый. 1939–86 елларда (бүленеп) К.Маркс исем. к-зда (Иске Урыссу) эшли: агроном (1955 тән), рәис (1959 дан); 1950–52 дә «Баштехснабнефть»нең Октябрьск базасында икътисадчы. Ю. җитәкчелегендә колхозда 70 тән артык җитештерү һәм социаль-көнкүреш объектлары төзелә. 1985 тә, 1959 ел б-н чагыштырганда, бөртекле ашлык җитештерү күрсәткечләре 2,2 тапкыр, сөт һәм ит — 2,3 тапкыр, бөртекле ашлык уңышы — 1 *га* дан 11,4 *ц* дан 25 *ц* га, уртача еллык савым һәр сыердан 2203 *кг* нан 2907 *кг* га кадәр арта. Җитештерүнең табышлылык дәрәҗәсе 36,7% тәшкил итә (1985). Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Р.Г.Газизуллина.*



Ш.С. Юсипов.



И.Ә. Юсупов.



Р.Г. Юсупов.

**ЮСУ́ПОВ** (Йосыпов) Исмаил Әкъсан улы (2.1.1922, Әстерхан ш. — 20.5.1992, шунда ук), Сов. Союзы Герое (16.10.1943), өлкән сержант. Владивосток шәһәрендә балык з-дында токарь булып эшли. 1940 елда Әстерханга кире кайта. 1941 нең декабреннән Кызыл Армиядә. 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында. 1943 нең 23 сентябрендә алдынгы төркем составында Комарин авылы янында (Белоруссия ССРның Гомель өлкәсе Брагин р-ны) Днепр елгасын кичеп чыга. Посудово авылына һөҗүм вакытында Ю. совет гаскәрләренә комачаулаган дошман пулемётын юк итә, яралана. Инвалидлык буенча демобилизацияләнгәннән соң (1944), Әстерханга кире кайта. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЮСУ́ПОВ** (Йосыпов) Рим Сөбханкол улы (10.8.1941, БАССРның Туймазы ш.), язучы, юрист. Куйбышев юридик ин-тын тәмамлый (1972). 1973 елдан Бохара шәһәрендә, адвокат, судья, Бохара өлкәсенең Юстиция идарәсе башлыгы урынбасары, 2003 тән Мәскәү янында (Руза р-ны Тучково пос.) яши. «Бохара» («Бухара», М., 1999) тарихи поэмасы, «Даһи» («Гений», А.С.Пушкин турында; М., 2007), «Романтик» (Байрон турында; М., 2009), «Салават йолдызы» («Звезда Салавата», С.Юлаев турында; М., 2010), «Тукай» (Г.Тукай турында; М., 2010), «Гомәр Хәйямның бөтен тормышы» («Вся жизнь Омара Хайяма», М., 2013) поэмалары, «Вакыт су кебек ага...» («И льётся время, как ручей»), «Аэлита, яки йөрәк күз яшьләре» («Аэлита, или слёзы сердца»), (икесе дә — М., 2012) китаплары авторы.

**ЮСУ́ПОВ** (Йосыпов) Риф Сәгъдәтулла улы (4.8.1964, БАССРның Чакмагыш р-ны Сыйрышбаш а.), гидротехника инженеры, а.х. фән. д-ры (1997), БРның атказ. а.х. хезмәткәре (2001). Башкорт а.х. ин-тын тәмамлый (1987, Уфа ш.). 1987 елдан Чакмагыш р-нында: «Алга» а.х. җитештерүе кооперативы (1998 гә кадәр Киров исем. колхозы) баш инженеры, рәисе, район хакимияте башлыгы (2003). Хезмәтләре зоотехниягә һәм терлекчелек продукциясе җитештерү технологиясенә карый.

Хезм.: Использование голштинов при совершенствовании бестужевского и чёрно-пёстрого скота. Уфа, 2003 (автордаш); Продуктивные качества молодняка бестужевской породы и её помесей с симменталами. Оренбург, 2004 (автордаш).

**ЮСУ́ПОВ** Рүзәл Габдуллаҗан улы (14.9.1938, Әтнә р-ны Кышкар а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1982), ТР ФА академигы (2007; 1992 елдан мөхбир әгъза), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1965), ТАССР МС каршында Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында тәрҗемәче һәм мөхәррир. 1970 тән Казан пед. ун-тында (2005 тән Татар гуманитар-пед. ун-ты): 1986–2002 дә ректор, 2002 дән татар тел белеме кафедрасы мөдире. 2011 дән Казан ун-тында: проф., 2012 гә кадәр хәзерге татар теле һәм аны укыту методикасы кафедрасы мөдире. Бер үк вакытта, 2007–09 да, ТР ФА вице-президенты. Хезмәтләре контрастив лингвистика, тәрҗемә теориясе һәм практикасы, татар сөйләме культурасы, татар телен укыту методикасына карый. Югары уку йортлары һәм урта мәктәпләр өчен татар теленнән дәреслекләр һәм уку-укыту ярдәмлекләре авторы. 1991–95 тә ТР ЮС депутаты. «Татар-рус телләре багланышлары: теория һәм практика» («Татарско-русские языковые связи: теория и практика», 1980–97) хезмәтләр циклы өчен 1998 дә ТР Дәүләт бүләгенә лаек була. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Әдәп башы — тел: Икетеллелек шартларында дөрес сөйләм мәсьәләләре. К., 2000; Икесен дә яхшы бел. К., 2000; Икетеллелек, тәрҗемә һәм сөйләм культурасы. К., 2007; Тәрҗемә мәсьәләләре. К., 2012; Вопросы перевода, сопоставительной типологии и культуры речи. К., 2005.

*Әд.:* Зыятдинов Ф. Яшәү мәгънәсе. К., 1998; Академик Рузаль Юсупов: Биобиблиогр. учёных Татарстана. К., 2007; Казанская лингвистическая школа. К., 2008.

**ЮСУ́ПОВ** (Йосыпов) Сөләйман Даут улы (25.7.1925, Лаеш кантоны, хәзер Теләче р-ны Алан а. — 20.2.2003, Казан, туган авылында җирләнә), җырчы, ТАССРның атказ. артисты (1960). В 1948–50 елларда Белоруссия хәрби округының җыр ансамбле артисты. 1950–64 тә ТАССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты, 1964–70 тә Татар филармониясе солист-вокалисты. 1990 га кадәр концертларда катнаша. Бәрхетсыман тембрлы көчле бас тавышка ия. Халык җырларын, татар композиторлары җырларын башкара. Татар муз. фольклор әсәрләрен җыя. «Татарстан» дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе (ДТРК) фондларында Ю.ның күп кенә язмалары саклана. «Умырзая», «Вәгъдә», «Әллүки», «Су буйлап», «Тәзкирә», «Җизнәкәй» кебек халык җырлары; Ж. Фәйзинең

«Яшь наратлар» җыры Ю. башкаруында аеруча популяр була.

*Әд.:* Арсланова Ф. Государственный ансамбль песни и танца Республики Татарстан = Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле: Посвящается 70-летию ансамбля. К., 2007.

**ЮСУ́ПОВ** (Йосыпов) Юныс Йосып улы (16.4.1926, ТАССРның Минзәлә кантоны Бикбау а. – 9.12.2018, Минзәлә ш., туган авылында җирләнә), төбәкне өйрәнүче. Минзәлә пед. уч-щесен (1953), Казан Югары партия мәктәбен (1960) тәмамлый. 1941–50 елларда Минзәлә р-нының «Корыч» к-зында эшли (1943–44 тә Совет Армиясендә хезмәт итә). 1950–86 да Минзәлә һәм Актаныш р-ннарында хуҗалык, совет һәм партия эшендә (КПСС район ком-тының оештыру бүлеге мөдире, Халык контроле район ком-ты рәисе). Күп еллар дәвамында Көнчыгыш Кама аръягы топонимнарын, риваятьләрен, легендаларын, торак пунктлары тарихы турындагы истәлекләрне туплый. Минзәлә, Актаныш, Тукай, Мөслим р-ннары авыллары, тарихи һәм мәдәни ядкәрләре, дини корылмалары, колхозлары, пр-тиеләре һәм учреждениеләре, атаклы кешеләре турында китаплар һәм вакытлы матбугатта мәкаләләр авторы. Минзәлә шәһәренең Мактаулы гражданы (1994). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006; Калморза — морзалар игы. Минзәлә, 2003; Бикбау авылы. Минзәлә, 2004; Адай авылы тарихы. Минзәлә, 2007; Тат. Әҗби: авыл һәм халык язмышы. Минзәлә, 2009; Авылдашлар. Минзәлә, 2011; Минзәлә мәчетләре. Минзәлә, 2011; Сагынам сине, Байларым. Минзәлә, 2012.

**ЮСУ́ПОВА** (Йосыпова) Әлфия Шәүкәт кызы (24.3.1966, Чүпрәле р-ны Иске Шәйморза а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2009), проф. (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1988), шунда ук эшли: 2008–13 елларда тәрҗемә теориясе һәм сөйләм коммуникациясе каф. мөдире, 2013 тән татар филологиясе һәм мәдәният ара коммуникацияләр бүлеге мөдире. 2015 тән Г.Тукай исем. татаристика һәм тюркология югары мәктәбе (2018 дән Г.Тукай исем. милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе) директоры. Хезмәтләре татар теленең 19 йөзгә караган икетелле лексикографиясенә, татар теле лексикологиясенә, диаспорада татар теле проблемаларына һ.б.га карый. Урта мәктәпләр өчен татар теленнән дәреслекләр һәм уку-укыту ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Кытайда яшәүче татарлар. К., 2014 (автордаш); Мордовия республикасы һәм Пенза өлкәсе татарлары: диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары. К., 2015 (автордаш); Чувашстан Республикасы татарлары: диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары. К., 2016 (автордаш). Двуязычная лексикография татарского языка XIX века. К., 2008; Лексикографическое и методическое наследие татарского языка (XIX век). К., 2010; Тюрко-татарская лексика как проекция национального менталитета. К., 2011.

*Әд.:* Казанская лингвистическая школа. К., 2008.

**ЮСУ́ПОВА** (Йосыпова) Гөлшат Гомәр кызы (25.1.1973, Яшел Үзән р-ны Мамадыш-Әкил а.), химик-органик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010), химия фән. канд. (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1995), 1997 елдан Органик һәм физик химия ин-тында. Хезмәтләре органик фрагментларның фуллеренга циклլап кушылу реакцияләрен тикшерүгә карый. Дәүләт бүләге «Фуллереннарның органик чыгарылмалары — органик электроника һәм биомедицина өчен наноматериаллар булдыруның «төзү» блоклары» эшендә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Изучение факторов, определяющих результат реакций циклоприсоединения изоциануратозамещённых азидов к [60] фуллерену // Изв. РАН. Сер. хим. 2001. № 11 (автордаш); Синтез индивидуального изомера бис-аддукта изоциануратозамещённого азида и [60] фуллерена // Изв. РАН. Сер. хим. 2002. т. 51, № 8 (автордаш); Синтез индивидуального региоизомера бис-аддукта по реакции фуллерена $C_{60}$ с трет-бутиловым эфиром 11-азидо-3,6,9-триоксаундекановой кислоты // Изв. РАН. Сер. хим. 2007. Т. 56, № 8 (автордаш).

**ЮСУ́ПОВА** (Йосыпова, ире буенча Щучинова) Лилия Җиһангир кызы (16.8.1957, Кемерово өлкәсенең Сталинск-Кузнецк ш.), табиб-эпидемиолог, мед. фән. канд. (2009), шагыйрә, тәрҗемәче, рәссам. Рус телендә яза. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1981), Горно-Алтайск шәһәрендә яши. Роспотребнадзорның Алтай Респ-касы буенча идарәсендә эшли (1991–97, бүленеп). «Үз тавышым» («Мой голос», 1996), «Очраклы булмаган очрашу» («Неслучайная встреча», 1998), «Үзгәрешләр китабы» («Книга перемен», 2000), «Сайланма әсәрләр» («Избранное», 2002), «Мәңге сүнмәс яктың, мәхәббәт...» («Твой вечный свет, любовь...», 2004), «Мәңгелекне уйлыйм туктаусыз...» («Я думаю о времени всегда...», 2006) (барысы да — Горно-Алтайск); «Сөю дәвере» («Время любви», 2010) (Барнаул) һ.б. китаплар авторы. Ю.ның шигърияте фәлсәфи тирәнлек, дөньяга ышанып карау б-н аерылып тора. Рус теленә шагыйрә Иделбикә шигырьләрен, Алтай шагыйрьләренең әсәрләрен тәрҗемә итә. Портретлар, натюрмортлар, көнкүреш жанрына караган нәкышь әсәрләре авторы. Рәссам буларак, аңа символик эчтәлек хас. Шәхси күргәзмәләре Омск (1995), Бийск (1999), Новосибирск (2005), Барнаул (2007) шәһәрләрендә уздырыла. *Р.Р.Мусабәкова.*

**ЮСУ́ПОВА** (Йосыпова) Татьяна Николаевна (31.5.1949, Казань), химик, химия фән. д-ры (2002), проф. (2008). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2015). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), Бөтенсоюз синтетик каучук фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында эшли, 1978 елдан Казан төзүче инженерлар ин-тында, 1983 тән — ВНИИгеолнерудта. 1984 тән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2002 дән). Хезмәтләре нефть химиясе, геохимиягә карый. Ю. яңа чыганаклардагы нефтьне типиклаштыру методологиясен аның составы һәм үзлекләренә хас сыйфатламалары комплексы буенча эшли, ш.у. диэлектрик релаксация мәгълүматлары нигезендә нефть дисперс системаларының җылылык китереп чыгарган фаза күчешләрен детектлау алымнарын эшләп чыгара. Оксидлашкан битумнарның коллоидлы төзелешен формалаштыруны билгеләүче асфальтен молекула өсте структураларның барлыкка килүен тикшерә. Нефть, эчендә нефть булган токымнар, асфальт-сумала-парафин матдәләр һәм нефть дериватларын термик анализлау алымнары комплексын тәкъдим итә.

Х е з м.: Структурно-групповой состав асфальтенов как показатель физико-химических процессов в продуктивных нефтяных пластах // Нефтехимия. 2005. Т. 45, № 6 (автордаш); Геохимическое исследование нефтей на последней стадии разработки месторождения // Нефт. хоз-во. 2006. № 3 (автордаш).

**ЮСУ́ПОВЛАР**, төрки-татар тамырлы нугай бәкләре нәселеннән чыккан Россия кенәзләре. Алтын Урда әмире *Идегәйдән* башлангыч ала. Ю. нәселе башында аның дүртенче буын варисы Нугай Урдасы бәге (1549–54), Казан ханбикәсе *Сөембикәнең* атасы *Йосыф* (? — 1554) тора. Аның уллары **Ибраһим морза** (?—?) һәм **Ил морза** (? — 1611) 1563 елда Нугай Урдасыннан Мәскәүгә патша Иван IV янына җибәрелә. Удел җире буларак аларга өязе б-н Романов шәһәре (хәзер Ярославль өлкәсе Тутаев ш.) бирелә. Бертуганнардан кенәз Ю.ның 17 йөздә христианлык кабул иткән ике тармагы үсеп чыга. Башта кенәз Ю.-Княжевлар дип, 17 йөз ахырыннан Ю. дип йөртеләләр. Ибраһим морза тармагы 18 йөз ахырында өзелә. Ил морза уллары — **Чин морза** һәм **Сейүш морза**. Ю. нәселенең иң танылган вәкилләре Сейүш морзаның кече улы Габдулладан (чукындыруда Дмитрий) (?—1694) тармаклана, ул патша стольнигы була. Ю. нәселенең күтәрелеп китүе аның улы, Пётр I нең көрәштәше, генерал-аншеф (1730) кенәз **Григорий Дмитриевич** (17.11.1676 — 2.9.1730, Мәскәү) исеме б-н бәйле. Пётр I вакытында стольник булып хезмәт итә башлый, Азов походларында (1695–96), Төньяк сугышында (1700–21), Нарва (1700), Полтава (1709) һәм Выборг (1710) янындагы сугышларда катнаша. 1719 дан генерал-майор, Хәрби коллегия әгъзасы, эзләнү-тикшерү эшләре канцеляриясен җитәкли, 1726 дан сенатор. Император Пётр II аңа Преображенский полкы подполковнигы чины бирә (1727) һәм Хәрби коллегиянең беренче әгъзасы итә. Беренчеләрдән булып Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә. Аның улы **Борис Григорьевич** (18.7.1695 — 26.2.1759, С.-Петербург), хакыйкый яшерен советник. 1717 дә Франциягә, Тулон гардемариннар уч-щесенә укырга җибәрелә. 1730 да хакыйкый камергер вазифасына билгеләнә, 1736 дан сенатор, 1738 дән Мәскәү вице-губернаторы, 1739 дан Мәскәү губернаторы, 1741 дән Коммерц-коллегия президенты, 1742 дән Ладога каналы директоры, 1750 дән коры җир шляхта корпусы баш директоры. Изге Андрей Первозванный ордены б-н бүләкләнә. **Николай Борисович** (15.10.1750 — 15.7.1831, Мәскәү), хакыйкый яшерен советник (1796), сенатор (1788). 1783–89 да Россиянең Сардиния короле сарае каршындагы Туриндагы гадәттән тыш илчесе һәм тулы вәкаләтле министры. 1791—99 да театрлар директоры, бер үк вакытта, 1792 дән, казна пр-тиеләре (пыяла, фарфор з-длары, шпалер мануфактурасы) б-н идарә итә, 1796 дан Мануфактур-коллегия президенты. Императорлар Павел I, Александр I

һәм Николай I гә таҗ кидерүләр вакытында Таҗ кидерү комиссиясе рәисе һәм югары маршал була. 1800 дән уделлар министры. 1802 дә барлык вазифаларыннан азат ителә; дәвалану өчен чит илгә китә. 1812 дә Мәскәүдә Гаскәрләрне азык-төлек б-н тәэмин итү ком-ты составына керә. 1823 тән Россия империясе Дәүләт советы әгъзасы. Нәкышь, скульптура әсәрләре коллекциясен туплый, зур китапханә калдыра. Изге Андрей Первозванный, Изге Иван Иерусалимский, 1 нче дәрәҗә Изге Владимир орденнары б-н бүләкләнә. **Борис Николаевич** (9.6.1794 – 25.10.1849), хакыйкый статский советник, гофмейстер (өлкән сарай чиннарының берсе) (1848). Сарайда церемониймейстер булып хезмәт итә. Петербург дворяннары өяз җыены җитәкчесе, аннары Царское Село дворяннары өяз җыены депутаты итеп сайлана. Петербург опекуннар советының шәрәфле опекуны, Финанс министрлыгы каршындагы Мануфактура советы әгъзасы һ.б. 1 нче дәрәҗә Изге Анна ордены б-н бүләкләнә. Аның улы **Николай Борисович** (12.10.1827 – 19.7.1891, Баден ш.), гофмейстер. Ю. нәселенең ир-ат буыннары буенча соңгы. Петербург ун-тын тәмамлый. Император гавами китапханәсе директоры ярдәмчесе. Рус-төрек сугышы вакытында 1853–56 да үз хисабына ике пехота батальонын киендерә, сугыш кирәк-яраклары б-н тәэмин итә һәм коралландыра. Хәйриячелек б-н шөгыльләнә:



Кенәз Николай Борисович Юсупов.
Рәссам Г.И.Новиков. 19 йөз башы.

Александр-Мария чукрак-телсезләр уч-щесе химаячесе, җәмәгать тәрбиясе йортларының Петербург советы әгъзасы, Демидов тәрбия йортының шәрәфле әгъзасы һ.б. Музыкантларга ярдәм итә, Рим һәм Париж консерваторияләренең шәрәфле әгъзасы. Асылташлар җыю б-н шөгыльләнә, иң зур бриллиант коллекцияләренең берсенә ия була. 4 нче дәрәҗә Изге Владимир ордены б-н бүләкләнә. Вафатыннан соң император Александр III Фәрманы буенча (1885) кызы княжна Зинаида Николаевнага һәм аның ире граф Ф.Ф.Сумароков-Эльстонга фамилияне һәм титулны кабул итүдә шарт куела: кенәз титулы һәм кушма фамилия фәкать алардан соңгы буыннарның өлкән вәкиленә генә күчә ала. Феликс Ю. Григорий Распутинны үтерүне оештыручы һәм анда катнашучы буларак билгеле (1916). Соңрак хатыны б-н Франциягә күчеп китә. Ю. Воронеж, Курск, Полтава, Харьков һ.б. губерналарда зур вотчина хуҗалары була.

*Әд.:* А х м е т ш и н Ш.К. Бархатная книга татар: Российские дворянские роды тюрко-татарского происхождения. СПб., 2010. Т. 1; Л я л и н В.Е. Князья Юсуповы. Кто они? Ростов н/Д., 2011.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ЮТАЗЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 45,2 *км*. Бассейнының мәйданы 390,5 *км*². Елга башы Бөгелмә р-нында, Аргуновка тимер юл станциясеннән 2 *км* көнбатыштарак, тамагы Ютазы р-ны Әпсәләм авылы янында. Елга башының абс. биеклеге



Ютазы елгасы.

280 *м*, тамагыныкы — 97 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Ю.ның 0,7 дән — 8,2 *км* га кадәр озынлыктагы 20 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Карамалы (8,2 *км*) — уң; Әтәмби (11,8 *км*), Урыссу (7,2 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*². Туенуы катнаш, өчтән ике өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 73 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 47 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпеллык чыгымы 0,35 *м*³/*с*. Язын суы каты (9–12 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Ю. бассейнында суының гомуми күләме 2 млн. *м*³ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ЮТАЗЫ́** авылы, Ютазы р-нында, район үзәге — шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 18 *км* көнбатыштарак, Ютазы елгасы буенда. Ульянов — Уфа юнәлешендәге тимер юл станциясе. 2010 елда 2095 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 83%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау.«Ютазы элеваторы» АҖ. 124 нче һөнәр уч-щесе, урта мәктәп, мәдәният йорты, 2 китапханә, дәвалау амбулаториясе. Мәчет, мәдрәсә. 1912 дә нигез салына. Оешкан көненнән Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумароково волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы р-ны үзәге, 1958 нең 28 февраленнән район үзәге Урыссуга күчерелә, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1926 да — 67, 1938 дә — 1097, 1949 да — 3010, 1958 дә — 2647, 1970 тә — 2766, 1979 да — 2427, 1989 да — 2389, 2002 дә — 2211 кеше.

**ЮТАЗЫ́ КЫМЫ́З ШИФАХАНӘСЕ́** посёлогы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 19 *км* көнбатыштарак, Ульянов–Уфа юнәлешендәге тимер юл станциясе янында урнашкан. 2010 елда 48 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — ат асрау. «Кымызтау» ял базасы. 20 йөз башында алпавыт дачасы буларак нигез салына. 1932 дә аның җирлегендә туберкулёз б-н авыручыларны дәвалау өчен Ю.К.Ш. («Ютазы» санаторие) ачыла, соңрак ул бөтенроссия санаторие статусын ала. Оешкан көненнән Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумароково волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 63, 1958 һәм 1970 тә — 84 әр, 1979 да — 91, 1989 да — 29, 2002 дә — 54 кеше.

**ЮТАЗЫ́ РАЙОНЫ́**, ТРның көньяк-көнчыгыш өлешендә, БР б-н чиктәш урнашкан. 1935 елның 10 февралендә оештырыла. Мәйданы — 760,6 *км*². 1 шәһәр һәм 10 авыл җирлеген (38 торак пункт) берләштерә. Үзәге — шәһәр тибындагы Урыссу посёлогы. Халкы — 20735 кеше (2017), (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 74,7%, руслар — 21,2%), ш.и. шәһәрләрдә — 10561, авылларда 10653 кеше яши (2014). Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 28,2 кеше. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязенә керә, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында, 1930 дан Азнакай, Баулы һәм Бөгелмә р-ннарында. 1940 та районның мәйданы — 1117 *км*², 16 авыл советы, 86 торак пункт (аларда 34,8 мең кеше яши) исәпләнә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1958 дә район үзәге Ютазы авылыннан шәһәр тибындагы Урыссу посёлогына күчерелә. 1960 та район 1323,4 *км*² җир били, 1 посёлок һәм 12 авыл советы, 97 торак пункт керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 фев-





П.С. Юхвитов.

ралендә район таркатыла, терр-ясе — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нына бирелә. 1991 нең 6 апрелендә район кабат торгызыла. Ю.р. Бөгелмә–Бәләбәй калкулыгында (биеклеге 90–330 *м*) урнашкан. Ык һәм аның кушылдыклары Дим, Ютазы елгалары ага. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, карбонатлы һәм типик кара туфраклы. Терр-ясенең 12% ы — урманлык. Нефть, газ, балчык, комташ-чуерташ катнашмасы, карбонат ятмалары бар. Саклаулы табигать объектлары: *Ык*, *Дим*, *Ютазы* елгалары, *Урдалы Тау* (Марков сөзәклеге). Район терр-ясендә бронза гасыр, Алтын Урда чорына караган 10 лап археол. истәлек, ш.и. *Бәйрәкәтамак каберлеге* табыла. А.х. җирләре — 52,7 мең *га*, сөрүлекләр — 39 мең *га* (2018). Сабан бодае, арыш, арпа, солы, карабодай, борчак, көнбагыш, рапс игелә. Мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау алга киткән. 2016 да районда 8 а.х. пр-тиесе, ш.и. Тукай исем. «Кәрәкәшле», «АгроМир» ҖЧҖләре эшли. Шәһәр тибындагы Уруссу посёлогында («ТГК Уруссу ГРЭСы» ЯАҖ, «Уруссу химия заводы» ҖЧҖ, «Электросоединитель» ААҖ, «Бетон+» ҖЧҖ, «Уруссу руда булмаган материаллар предприятиесе» ҖЧҖ), Ютазы («Ютазы элеваторы» ААҖ), Әпсәләм («Әпсәләм төзелеш конструкцияләре һәм материаллары комбинаты» ҖЧҖ, «Волма-Абсалямово» ҖЧҖ, «Юлчы» ҖЧҖ ф-лы), Алабакүл («Алабакүл кирпеч заводы» ҖЧҖ) авылларында сәнәгать пр-тиеләре эшли. Ю.р. терр-ясеннән Ульянов — Уфа (Уруссу — Октябрьский тармагы б-н) тимер юлы, Азнакай — Баулы автомобиль юлы уза. Районда 13 гомуми белем бирү мәктәбе, гимназия, балалар сәнгать мәктәбе, «Олимп» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе; балалар иҗаты үзәге, 1 балалар һәм 18 гаммави китапханә, 20 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 21 клуб, район үзәк хастаханәсе, 2 дәвалау амбулаториясе эшли. Татар һәм рус телләрендә «Ютазы таңы»-«Ютазинская Новь» район г-талары нәшер ителә.

**ЮФТЬ**, катнаш иләнгән йомшак күн. Ю. җитештерү Идел буе Болгар дәүләте заманыннан ук мәгълүм. Казан губернасында Ю. 18–19 йөзләрдә киң таралыш ала. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, ат тиреләрен эшкәртеп әзерләнә. Аяк киеме, ш.и. итекләр (читекләр), сандалилар, дирбия-ияр эшләнмәләре җитештерү өчен кулланыла. Ю. нең йомшаклыгына, суга чыдамлылыгына һәм сыгылучанлыгына алдан май б-н эшкәртү һәм озаклап көлләү нәтиҗәсендә ирешелә. Күн җитештерүнең 1990–2000 елларда яңарыш кичерүе сәбәпле, Ю. Татарстанның кайбер р-ннарында (Арча, Биектау) яңадан җитештерелә башлый. Ш.у.к. *Аяк киеме*.

*Әд.:* Г у л о в а Ф.Ф. Татарская национальная обувь: Искусство кожаной мозаики. К., 1985; Х а л и к о в Н.А. Промыслы и ремёсла татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX вв.). К., 1998. Саттарова Л.И. Казанская узорная кожа. М., 2004.

**ЮХА́** (Юха елан), татар мифологиясе һәм фольклоры персонажы. Башкортлар, төрекмәннәр һәм Шәрекъның кайбер башка халыклары фольклорында очрый; явыз, хәйләкәр һәм куркыныч, кешегә дошман зат, геройның капма-каршысы, убыр. Яшь егет, еш кына гүзәл кыз кыяфәтенә керә. Кеше, бернәрсәдән дә шикләнмичә, Ю. б-н никахлаша һәм һәлак була (мәс., татар халкының «Аучы», «Чәчәк күлмәк» әкиятләре һ.б.). Ю. судан курка. Ю.дан бер генә котылу юлы бар — аны кызу мунчада ябып үтерү (мәс., татар халык әкияте «Ярлы егет белән Юха елан» һ.б.). Ышанулар буенча, 1000 яшькә кадәр яшәгән елан Ю.га әйләнә. Ю. турындагы әкиятләрнең барлыкка килү, таралыш тарихын өйрәнү, аларны теркәү б-н К.Насыйри шөгыльләнә.

*Әд.:* Җ а м а л е т д и н о в Л.Ш. Тылсымлы әкиятләрдә елан белән бәйле мифологик образлар // Борынгы татар фольклоры мәсьәләләре. К., 1984; Н а с ы й р и К. Казан татарларының ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр // Сайланма әсәрләр. К., 2005. Т. 3; Мифы народов мира: Энцикл. М., 1988. Т. 2.
*М.Х.Бакиров.*

**ЮХВИ́ТОВ** Пётр Сергеевич (1.10.1918, Сембер губ. Буа өязе, хәзер Чүпрәле р-ны Хорновар-Шигали а. – 14.8.1944, Украина ССРның Ивано-Франковск өлкәсенең шәһәр тибындагы Бурштын посёлогында җирләнә), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, үлгәннән соң), гв. өлкән лейтенанты. Батышев пед. уч-щесен (1937), Төмән хәрби-пехота уч-щесен (1941) тәмамлый. Туган авылында мәктәптә укыта. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1943 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 873 нче укчы полкта (1 нче гв. армиясенең 276 нчы укчы дивизиясе) рота командиры. 4 нче Украина фронты гаскәрләре составында Львов-Сандомир һөҗүм операциясендә катнаша (1944). 1944 нең 12–14 августында Коростеньки авылы (Украина ССРның Ивано-Франковск өлкәсе Галич р-ны) янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: сугышчылар төркеме б-н әһәмиятле биеклекне яулап ала; дошманның берничә контрһөҗүмен кире кайтара; шушы сугышта һәлак була. Ленин ордены, Александр Невский, Кызыл Йолдыз орденнары, медаль б-н бүләкләнә. Туган авылында бер урамга һәм урта мәктәпкә Ю. исеме бирелә, бюст куела. Геройның исемен Ивано-Франковск өлкәсенең Галич р-ны Кинашев урта мәктәбе йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.
*М.З.Хәбибуллин.*

**ЮХМАЧЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Кече Чирмешән елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 15,7 *км*. Бассейнының мәйданы 66,7 *км*$^2$. Идел аръягы түбәнлегеннән ага. Елга башы Спас р-ны терр-ясендә, «Бәрән урман дачасы»ның көньяк-көнчыгышында, тарихи вал янында; тамагы Әлки р-ны Юхмачы авылыннан 1 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 138 *м*, тамагыныкы — 73 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,24 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, өчтән ике өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 73 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 50 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,045 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЮХМАЧЫ́** авылы, Әлки р-нында, район үзәге Базарлы Матак авылыннан 35 *км* көньяктарак, Юхмачы елгасы буенда. 2010 елда 771 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 62%, татарлар — 28%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Май з-ды, урман хуҗалыгы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1698 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Успенское-Ухмачи исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, арба һәм мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Успение чиркәве, земство мәктәбе (1877 дә ачыла), фельдшерлык пункты, 4 тегермән, 3 тимерче алачыгы, май язу йорты, 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете була; пәнҗешәмбе базары эшли, 14 сентябрьдә ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1343 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Юхмачы волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы р-ны үзәге, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 114 ир-ат; 1859 да — 777, 1897 дә — 1235, 1908 дә — 1395, 1920 дә — 1574, 1926 да — 1275, 1938 дә — 930, 1949 да — 1085, 1958 дә — 1071, 1970 тә — 1133, 1979 да — 1009, 1989 да — 898, 2002 дә — 817 кеше.

**ЮХМАЧЫ́ РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1944 елның 19 февралендә оештырыла. Үзәге — Юхмачы авылы. 1920 гә кадәр район терр-ясе Казан губернасының Спас өязенә керә, 1920 дән — ТАССРның Спас кантонында, 1930 дан — Әлки, 1935 тән Әлки һәм Кузнечиха р-ннарында. 1948 дә Ю.р. 15 авыл советын һәм 43 торак пунктны берләштерә. 1956 да мәйданы — 801,5 *км*$^2$, 13 авыл советы һәм 43 торак пункт исәпләнә. 1956 ның 7 де-

кабрендә Ю.р. бетерелә, терр-ясе Әлки һәм Кузнечиха р-ннарына бирелә.

**ЮШКО́** Сергей Владимирович (3.3.1971, Белоруссия ССР, Минск өлкәсенең Молодечно ш.), мәгълүмати технологияләр өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2001), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2010). 1994 елда Казан технник ун-тын тәмамлый, Казан технол. ун-тында эшли (бүленеп: 1997–2001 дә Бөтенроссия чыгым үлчәү фәнни-тикшеренү ин-тының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре), 2001 дән инженерлык, компьютер графикасы һәм автоматлаштырылган проектлау каф. мөдире, 2006 дан мәгълүмати технологияләр ф-ты деканы, проф. (2004). Бер үк вакытта, 2004 тән, «Идея» технопаркының (Казан) инновацияләр буенча директоры, 2006 дан «Идея» инновация-җитештерү технопаркы директоры. Хезмәтләре эчке мәсьәлә шартларында газлар һәм сыекчаларның турбулент агымнарын эксперименталь һәм микъдари тикшерүләргә карый. Ю. технол. процессларның автоматлаштырылган идарәсе һәм энергия йөртүчеләрне исәпләү системалары өчен газлар һәм сыекчаларның физик-химик үзлекләрен хисаплау алгоритмнарын эшли (илебезнең нефть-газ комплексы пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). Зур фәнни чыгымнар таләп итүче технологияләрне коммерциализацияләү, кече инновацияләр бизнесын үстерү һәм респ-када технопарклар челтәрен булдыру проектларын җитәкли. 2003 тән ТР Яшь галимнәр һәм белгечләр советы рәисе. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Моделирование импактных струй и их возможное применение в промышленности // Тепло-массообменные процессы и аппараты химической технологии. К., 2002 (автордаш); Газодинамический стенд для изучения стационарных и нестанционарных турбулентных воздушных потоков в трубах // Вестн. Казан. технол. ун-та. 2012. Т. 15; Основные требования к формам наконечников измерителей содержания дисперсной фазы в газовом потоке // Газовая пром-сть. 2013. № 2 (автордаш).

**ЮШКО́В** Николай Фирсович (якынча 1846, Казан — 1912), музыка һәм театр тәнкыйтьчесе, язучы. Казан ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый. 1873 елга кадәр Казан губернаторы каршында коллежский асессор чинында махсус вазифалар башкаручы чиновник булып эшли. 1875–95 тә, башка мәгълүматларга караганда, 1872–91 дә (сәяси ышанычсызлыгы аркасында вазифасыннан читләштерелүгә бәйле рәвештә бүленеп) «Казанские губернские ведомости» г-тасында бүлек мөдире. 1891 дә концерт оештыра, аннан җыелган керем сәяси тоткыннарга каралган була. Соңыннан Казан өяз земство идарәсе секретаре, Россиядәге беренче телеграф агентлыгы агенты. Казанда Нәфис сәнгать сөючеләр җәмгыятен оештыручыларның берсе. Музыка һәм театр сезонына кагылышлы вакыйгаларны газета битләрендә яктыртып бара. 1909 да «Вечерняя почта» г-тасында Ф.Шаляпинның Казандагы соңгы чыгышы турында мәкалә бастыра, ул мәкаләдә автор җырчының артистлык талантын Л.Толстойның сүз сәнгатендәге даһилыгы б-н чагыштыра. Рус әдәбияты һәм театры турында китаплар авторы, ш.у. драматург һәм прозаик буларак чыгышлар ясый. Ю.ның Россия буйлап сәясәте яктыртылган «Юл очерклары һәм манзаралары» («Путевые очерки и картины», Пенза, 1878) китабы танылу ала. Н.Котин, П.Ломов псевдонимнары һәм үз фамилиясе б-н басыла.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ЮШКО́ВА Л.Г.НЫҢ КИТА́П КИБЕТЕ́ ҺӘМ КИТАПХАНӘСЕ́**, Казанда. 1874 елда «Шәрекъ лирасы» («Восточная лира») нота-музыка кибете ачыла. Башта анда музыка уен кораллары, алга таба — китаплар, альбом һ.б. рәсемле басмалар, опера либреттолары, журнал һәм газеталарның аерым санндары сатыла. Вакыт узу б-н, нота уку өчен абонемент, театраль китапханә оеша, балалар китаплары сатыла башлый, газета һәм журналларга язылу кабул ителә. «Шәрекъ лирасы» китап-музыка һәм музыка уен кораллары кибете ноталары каталогы» («Каталог нот книжно-музыкального и инструментального магазина «Восточного лира», 1883) басыла. 1883 тә бина хуҗасы Л.Г.Юшкова кибет каршында җәмәгать файдалануындагы китапханә һәм уку өчен кабинет ачу артыннан йөри, әмма ире Н.Ф.*Юшковның* шик астына алынган булуы аркасында үтенече кире кагыла (рөхсәт 1890 да бирелә). «Шәрекъ лирасы» 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Казандагы иң эре җәмәгать китапханәләренең берсе була. 1892 еллардагы мәгълүматларга караганда, китапханәдә 6478 исемдәге китап (14724 том) исәпләнә, алардан, укырга ноталарны алып торган кебек, 388 абонент файдалана; 1893 тә 11200 сумлык 7105 исемдәге китап (15675 том) һәм 547 абонент исәпләнә. 1899 да китапханә фонды 17820 сумлык 10835 исемдәге төрле китапка (21364 том) ия була, әдәбияттан 1195 абонент файдалана, 1900 дә — 18940 сумлык 11250 исемдәге китап (22950 том).

*Әд.:* Г а б д е л ь г а н е е в а Г.Г. Книжная торговля в Казанской губернии: вторая половина XVIII в. — 1917 г. К., 2006.

*Г.Г.Габделганиева.*

**ЮШМА́Н** (фарсы. یوشمان — җавшан), күкрәк һәм җилкә ягында горизонталь пластиналар үрелгән көбә рәвешендәге сугыш киеме. 12–15 *кг* авырлыкта булган. Ю. әзерләү өчен 100 ләп пластина кулланылган; җыйганда алар аз гына бер-берсе өстенә кертеп беркетелгән. Кайбер очракта пластиналар өслегенә алтын яки көмеш йөгертелгән. 15–16 йөзләрдә Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында киң таралган.

*Әд.:* Г о р е л и к М.В. Монголо-татарское оборонительное вооружение второй половины XI — начала XV вв. // Куликовская битва в истории и культуре нашей Родины. М., 1983.

*И.Л.Измайлов.*

**ЮЫНЧЫ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 48 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 175 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Чунчелеева исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1884 тә төзелә), мәктәп, 2 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 996,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Цивильск өязе Яңа Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1716 да — 92, 1747 дә — 183, 1782 дә — 129 ир-ат; 1859 да — 595, 1897 дә — 879, 1908 дә — 1133, 1920 дә — 883, 1926 да — 773, 1938 дә — 877, 1949 да — 451, 1958 дә — 464, 1970 тә — 453, 1979 да — 342, 1989 да — 247, 2002 дә — 203 кеше.

# Я

**ЯБАЛА́К** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 12 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 280 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17-18 йөзләрдә нигез салына. 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.та мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, ярма яргыч, тимерче алачыгы, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1414,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасы Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 124 ир-ат; 1859 да — 851, 1897 дә — 1179, 1908 дә — 1313, 1920 дә — 1214, 1926 да — 846, 1938 дә — 1369, 1949 да — 728, 1958 дә — 811, 1970 тә — 649, 1979 да — 316, 1989 да — 309, 2002 дә — 299 кеше.

**ЯБАЛА́К** (Рус Ябалагы) авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 9 *км* көньяктарак, Бәрле елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 195 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 72%, татарлар — 27%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, чөгендер үстерү. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Ебалакова, Эбалаки исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә һәм тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Владимир Богородица чиркәве, земство мәктәбе (1880 дә ачыла), 2 җил тегермәне, казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1277 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 94 ир-ат; 1859 да — 719, 1897 дә — 1308, 1908 дә — 1621, 1920 дә — 1596, 1926 да — 1274, 1938 дә — 1396, 1949 да — 1079, 1958 дә — 811, 1970 тә — 649, 1979 да — 477, 1989 да — 309, 2002 дә — 260 кеше.

**ЯБАЛАКЛА́Р** (Strigidae), ябалаксыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. 123 төре билгеле, Антарктидадан кала барлык җирдә дә киң таралганнар. Татарстан терр-ясендә 12 төре бар: *байгыш*, ак ябалак (Nyctea scandiaca), колаклы ябалак (Asio otus), сазлык ябалагы (A. flammeus), йокычан ябалак (Otus scops), йөнтәс аяклы ябалак (Aegolius funereus), йорт ябалагы (Athene noctua), чыпчыксыз ябалак (Glaucidium passerinum), карчыгасыман ябалак (Surnia ulula), *соры ябалаклар* (соры, озын койрыклы, сакаллы). Башы зур, 270 градуска борыла ала. Күзләре зур, алга карый. Каурый капламы йомшак, күпереп тора, бу Я.га тавышсыз гына очарга мөмкинлек бирә. Бик яхшы ишетәләр, тире җыерчыкларыннан, каты каурыйлардан торучы тышкы колак яфраклары һәм каты каурыйлы бит дискы ярдәмендә тавыш чыганагының урынын төгәл билгелиләр. Томшыгы ыргаксыман, төбендә каты тире капламы бар. Барлык ерткыч кошларныкы кебек, аяклары зур тырнаклы, алар ярдәмендә корбаннарын эләктерәләр һәм аны һавага күтәрәләр. Ак ябалак Татарстан терр-ясенә ноябрь-декабрьдә килә, март-апрельдә китә. Ата кошлар тоташ ак яки сирәк кенә аркылы кара тимгелләр төшкән ак төстә, ана кошларның аркасы көрән чуар, түшендә аркылы көрән буйлар бар. Колаклы ябалак — аз санлы утрак төр. Каурый капламының төсе аксыл-көрәннән кара-көрәнгә кадәр. Аркасы карарак, түше җирәнрәк, кара чуар саргылт төстә. Сазлык ябалагы — күчмә кош. Ачык биотопларда: кисенделәрдә, тугай болыннарында, сазлыкларда, аланнарда яши. Төп төсе — сары-көрән. Аркасындагы каурыйлары аксыл каймалы көрән төстә. Түше ян-якларында тар һәм күкрәгендә киңрәк булган озынча кара тимгелле җирән-сары. Йокычан ябалак март ахыры — апрель башында килә. Агачлар үскән төрле ландшафтларда яши. Төсе тимгелле көрән-сорыдан көрән-җирәнгә кадәр, түше аксылрак. Бит дискы бик күренми һәм кара тимгелләр б-н чуарланган. Канатлары озын, койрыгы чагыштырмача кыска. Йөнтәс аяклы ябалак — оя коручы утрак төр. Аяк бармаклары тырнакларына кадәр каурый б-н капланган, «йөнтәс аяклы» исеме шуннан. Аркасы аксыл түгәрәк таплы аксыл-көрән. Түше сузылып киткән кара бизәкле аксыл төстә. Йорт ябалагының яшәү тирәлеге, нигездә, респ-каның көнбатыш һәм көньяк районнары. Утрак кош. Чормаларда, ташландык таш корылмаларда һ.б. ышык урыннарда (бу үзенчәлеге кошның исемендә дә чагылыш тапкан) оялый. Тыгыз гәүдәле. Канатлары һәм койрыгы озын. Чыпчыксыз ябалак — Я.ның иң кечкенә вәкиле (озынлыгы якынча 17 *см*, авырлыгы 70 *г* тирәсе). Кама алдында яши. Койрыгында аксыл 5–6 аркылы сызык бар. Бит дискы бик күренми. Карчыгасыман ябалак — утрак яки күчеп йөрүче кош. Аркасы ак тимгелле кара-көрән, түше аркылы кара бизәкле ак. Бит дискы бик күренми, аксыл, кара буй б-н каймаланган. Койрыгы озын, киртләч, аркылы буй-буй. Көндезге яшәү рәвеше алып бара. Я. ояларын агач куышларында яки җирдә коралар. 3–6 йомырка салалар. Кечкенә кошлар, тычкансыман кимерүчеләр, җир тычканнары, зур бөҗәкләр һ.б. б-н тукланалар. Барлык төрләре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Колаклы ябалак.

**ЯБАЛАКЧЫКЛА́Р**, т ө н  я р к а н а т л а р ы (Noctuidae), күбәләкләр семьялыгы. Чагыштырмача 15 ассемьялыкка: ук күбәләкләр, кимерүче ябалакчыклар, тасмачлар, металлсыман күбәләкләр, чын ябалакчыклар һ.б.га (кайберләренең Я.га керүе бәхәсле) бүленәләр. 25 меңнән артык төре билгеле (күбәләк семьялыкларының төрләр саны буенча иң күпсанлысы), киң таралганнар, Россиядә — 2 меңнән артык төр, Татарстан терр-ясендә төгәл саны билгеләнмәгән.Тышкы кыяфәте б-н миниатюр ябалакларга охшаш (исеме шуннан): зур булмаган башы йомшак төкчәләрдән торган башлык б-н әйләндереп алынган, күзләре ялтырый. Аеруча бу зур Я. — тасмачлар: зәңгәр, кызыл, сары күбәләкләр, тирәк тасмачы өчен хас. Киң күкрәге куе төкчәләр б-н капланган, корсагы юан. Канат җәеме, гадәттә, 25–35 *мм*; алгылары — озынча, өчпочмаклы, еш кына 5 аркылы сызыклы һәм 3 таплы соры яки көрән төстә, арткылары — түгәрәк, аксыл, сирәк кенә төслеләр. Я. күбесенчә төнлә һәм караңгылы-яктылы вакытта активлар (икенче исеме шуннан); көндез канатларын җыеп тыныч кына агачларда утыралар. Гусеницалары, гадәттә, ялангач, 5 пар корсак аяклы. Яфраклар б-н туеналар, кайвакыт җимеш һәм ботакларны да кимерәләр, сирәк кенә лишайникларда, коелган яфракларда, үсемлекләрнең җир асты өлешләрендә яшиләр. Я., мәс., уҗым ябалакчыгы (Agrotis segetum), кәбестә ябалакчыгы (Mamestra brassicae), нарат ябалакчыгы (Panolis flammea) күпләп үрчегәндә а.х., урман һәм җимеш культураларына җитди зыян китерәләр. Тирәк тасмачы (Limenitis populi) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*С.Г.Гордиенко.*

**Я́БЛОКОВ** Андрей Поликарпович (1854 — 31.3.1933, Казан), дин эшлеклесе, төбәкне өйрәнүче, археолог. Казан руханилар академиясен тәмамлый. 1892–1918 елларда *Благовещение кафедраль соборының* ачкыччысы,

соңрак протоиерее, башлыгы, бер үк вакытта хосусый миссионерлык ятимханәсе җитәкчесе була. 1918 нең сентябрендә акгвардиячеләр б-н Казаннан китә, ләкин тиздән әйләнеп кайта һәм Ярославль могҗиза тудыручылар чиркәвендә эшли. Хезмәтләре борынгы чиркәү ядкәрләренә, православие архит-расы истәлекләренә, ш.и. Казандагы Благовещение соборына, Зөядәге монастырьлар һәм храмнар тарихына карый.

Х е з м.: Первоклассный мужской Успенско-Богородицкий монастырь в г. Свияжске Казанской губернии. К., 1906; Город Свияжск Казанской губернии и его святыни: Ист.-археол. очерк. К., 1907.

*Әд.:* Е л д а ш е в А.М. Утраченные монастырские некрополи Казани: XVI — начало XX вв. К., 2008.

**Я́БЛОКОВ** Василий Андреевич (31.7.1892, Казан — 2.8.1975, шунда ук), математик, педагог, проф. (1931), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1954). 1916 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, гомуми математика кафедрасын оештыра һәм аның мөдире була (1937–41, 1944–75), физика-матем. ф-ты деканы урынбасары (1933); бер үк вакытта шәһәр ин-тларында укыта (бүленеп: 1918–20 дә Омск ш. институтларында). Хезмәтләре проектив һәм дифференциаль геометриягә, вариацияле исәпләп чыгаруга, дифференциаль тигезләмәләрне интеграцияләү мәсьәләләренә карый. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр; ТАССР ЮСның Мактау кәгазе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О взаимно полярных конических сечениях // Изв. Физ.-мат. об-ва и НИИ математики и механики при Казан. ун-те. Сер. 2. 1933. Т. 23; Экстремальные значения функций многих переменных: Учеб. пособие. К., 1962; Теория поля: Учеб. пособие. К., 1963; Дифференцирование сложных и неявных функций. К., 1971.

**Я́БЛОКОВ** Юрий Васильевич (10.9.1933, Казан — 25.4.2012, шунда ук), физик, физика-матем. фән. д-ры (1974), проф. (1981), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1956), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли, сектор мөдире (1978 дән), каты җисем ЭПР лаб-ясе мөдире (1979 дән), баш фәнни хезмәткәр (1993 тән). 2000–07 еллардан Польша ФАнең Молекуляр физика ин-ты профессоры. Хезмәтләре магнетик күренешләр физикасына, каты җисем радиоспектроскопиясенә, виброн тәэсир итешүләргә карый. Я. беренче булып бирадикалларда ЭПР күзәтә. Үзара бәйләнеше көчсез димерлардан төзелгән нәорганик полимер чылбырларда «триплет экситоннар» исемендә билгеле миграцияләүче триплет ярсуларны таба һәм тикшерә. Тио-семикарбазонат $Fe^{3+}$ классы кушылмаларындагы югары спин — түбән спин күчеше процессы түбән симметрияле фаза доменнары хасил булуы аша башкарылуын күрсәтә. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Парамагнитный резонанс обменных кластеров. М., 1988 (автордаш); The beginning of Paramagnetic Resonance Singapore-L.–N.Y., 1994 (автордаш); Exchange interactions and Electron delocalization in the mixed-valence cluster V4IVV2VO7(OC2H5)12 // Inorg. Chem. 2008. V.47.

*Р.Г.Усманов.*

**ЯБЫ́К ГРУНТ**, ясалма микроклимат булдыру яисә табигый микроклиматны яхшырту юлы б-н яшелчә, декоратив, җиләк-җимеш үсемлекләрен, үсентеләр һәм гөмбәләр үстерү өчен билгеләнгән корылмалар (теплицалар, парниклар, җылытылган грунт). Я.г. яшелчәчелек һәм чәчәкчелекне төньяк районнарда җәелдерергә, ел дәвамында продукция алырга, үстерелә торган а.х. культураларының ассортиментын киңәйтергә мөмкинлек бирә. Корылмаларның гади төрләренә җылытылмый торган грунт — түтәлләр, салкын үрентеләр урыны һәм салкын төннәрдә җылы чыгармый торган материаллар б-н каплана торган тигез өслекле кишәрлекләр керә. Культивацияле корылмаларның төп төре — кышкы һәм язгы теплицалар. Кышкы теплицалар ел дәвамында яшелчә продукциясе җитештерү өчен файдаланылалар, алар микроклимат б-н, сугаруны көйләүне, углекислый газ, минераль ашламалар эремәсен бирүне автомат идарә итү системасы б-н җиһазландырылган. Язгы теплицалар, пыяла яисә плёнка б-н капланган, яз башыннан көзгә кадәр файдаланылалар. Теплицаларның махсус тибы — шампиньон үстерә торган корылма. Татарстанда беренче Я.г. сәнәгать пр-тиесе буларак 7 нче Казан теплица-парник комб-ты барлыкка килә (1956, 1964 тән — Казан теплица с-зы), анда 4,9 *га* мәйданда Я.г.та яшелчә үстерү 1956 елда 116,2 *т*, 2003 тә 1750 *т* тәшкил итә. ТРда теплицаларның гомуми мәйданы якынча 150 *га*, шулардан кышкылары — 97,6 *га*, язгылары — 48,7 *га*, җылытылган грунт — 200 *га* дан артык, шампиньон үстерә торганнары — 1 *га*. Иң зур кышкы теплицалар Яшел Үзән р-нының «Майский» с-зында (49 *га*), Тукай р-нының «Весенний» с-зында (31 *га*, ш.и. шампиньон үстерә торганы 1 *га*) төзелә. Я.г.та уртача еллык яшелчә үстерү ТР буенча 27–30 мең *т* тәшкил итә. Кышкы теплицаларда уңыш 1 $м^2$ дан 33–35 *кг* һәм аннан да артык алына.

**ЯБЫШКА́К ҮЛӘ́Н** (Turritis), әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан бер- һәм икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Дөнья флорасында 3 төре билгеле, Европа, Азия, Африка тауларында очрыйлар. ТР терр-ясендә бер төре — шома Я.ү. (T. glabra) бар. Барлык районнарда, кырларда, коры тау битләрендә, урман буйларында үсә. 35–120 *см* биеклектәге икееллык үсемлек. Сабагы туры, шома. Балавызсыман куныклы булганлыктан, үсемлек күгелҗем төстә. Аскы ягы ак төкчәле. Тамыр яны яфраклары — ланцетсыман, сирәк тешчәле, сабак яфраклары — озынча түгәрәк-ланцетсыман. Чәчәкләре вак, саргылт, чук чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — кузакчык. Июнь-июльдә чәчәк ата. Дару үсемлеге. Җир өсте өлешләре корсакка сары су җыелу, ревматизм, чәнчүләр вакытында файдаланыла.

**Я́ВИШЕВ** Бари Габдулла улы (19.9.1943, Ленинград), биофизик, биол. фән. д-ры (1991), физика-матем. фән д-ры (1992). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1968), шунда ук эшли (бүленеп: 1971–73 тә СССР РФАнең Казан ф-лында), 1974–84 елларда үсемлекләр физиологиясе каф. лаб-ясе мөдире, 1991–96 да әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 2007 дән Социаль һәм гуманитар фәннәр ин-тында (Казан). Хезмәтләре үсемлекләр физиологиясенә, су алмашуга, биопроцесслар фоторегуляциясенә һәм цитогенетикага карый. Күкертле радиопротекторлар б-н күзәнәкнең радиорезистентлыгын көчәйтү механизмын таба. Яктылык б-н биоструктуралар тәэсир итешкәндә су молекулаларының структур-функциональ ролен билгели. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Применение метода спинового эха для изучения дейтерообмена низко- и высокомолекулярных соединений // Зависимость физиологической роли воды от её состояния. К., 1972; Исследование формирования комплексов Cu(II) в формамидных электролитах // Электрохимия. 1975. Т. 2, № 9 (автордаш); Физическая активация водных систем. Л., 1975.

**Я́ГОДНЫЙ БИСТӘСЕ́**, 16 йөздә Казанның төньяк-көнбатыш читендә, *Бишбалта бистәсе* янында барлыкка килгән торак пункт. Чагыштырмача коры, калку урында — Җиләкле урман һәм Җиләкле авылы булган Елантау тирәсендә урнаша. 1552 елда Казан басып алынганнан соң, татарлар ул урыннардан куыла, ә бистә барлык җирләре белән воевода Пётр Булгаковка (Ростов кенәзләре нәселеннән) бирелә. 1584 тә бу җирләр Казан епархиясе биләмәсенә күчә, Ягодная Поляна авылы архиепископ Тихонның шәхси милкенә әверелә. 18 йөз уртасында Казан епархиясенең вотчина җирләре исәбеннән чыгарыла һәм Казан губернасы Казан өязе Ягодный авылы дип атала башлый. Хәзерге Архангельский урамы, нигездә, элекке авыл урамы рәвешен кабатлый, Ягодный урамы да үзенең атамасын саклый. Ул 1806 ның 18 июлендә ачылган һәм рев-циягә кадәрге рәсми документларга 3 нче шәһәр уч-щесе буларак кергән (хәзерге Гладилов урамында) Ягодный башлангыч уч-щесе бинасы Я.б.нең тарихи истәлеге булып исәпләнә. Я.б. терр-ясендә тире эшкәртү, җилем кайнату һәм аркан ишү вак һөнәрчелек пр-тиеләре урнаша. 1776 да Я.б.ндә — 93, 1796 да — 106, 1879 да 6328 йорт була.

*Әд.:* Б и к б у л а т о в Р., М у с т а ф и н Р. Казань и её слободы. К., 2001; М а н с у р о в а Ю. «Откуда есть пошла Адмиралтейская слобода...» // Гасырлар авазы — Эхо веков. — 2005. № 2.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ЯГЪКУ́Б** Вәлиулла (Якупов Винер Мәхмүт улы) (4.9.1963, БАССР, Уфа р-ны Дмитриевка а. — 19.7.2012, Казан), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарих фән. канд. (2004). Казан химия-технол. ин-тын (1987), Ислам дине кабул итүнең меңьеллыгы исем. мәдрәсә (1993) тәмамлый. 1990 елдан башлап «Иман» ислам мәдәнияте үзәге рәисе, 1992 дән Апанай мәчете имам-хатибы, бер үк вакытта, 1993–96 да, «Мөхәммәдия» югары мөселман мәдрәсәсе ректоры, 1996–98 дә Казан шәһәренең имам-мөхтәсибе була. 1998 дән ТР Диния нәзарәте рәисенең 1 нче урынбасары, 2011 дән уку-укыту бүлеге мөдире вазифасын башкара. Татарстан мөселманнарының беренче дини «Иман» нәшрияты директоры һәм «Иман» г-тасы (1991 дән) нашире, «Иман нуры» (1994 тән) һәм «Мөселман дөньясы»


С.Ф.Ягъфәров.


Я.Җ.Ягъфәров.

(1998 дән) ж-лларының мөхәррире буларак, дини мәгърифәтчелек әдәбияты, Россия һәм Татарстан мөселманнарының дини һәм этномилли мәгарифе үсешенә зур өлеш кертә. ТР Иҗтимагый палатасы әгъзасы (2007 дән), РФ Юстиция министрлыгы каршындагы дини экспертиза советы рәисе урынбасары (2009 дан) була. Хезмәтләре исламны өйрәнүгә, Татарстанда дәүләти-конфессиональ мөнәсәбәтләр тарихына карый. Террорчылык акты нәтиҗәсендә фаҗигале рәвештә һәлак була, Кыюлык, Россия мөфтиләре Советының 2 нче дәрәҗә «Әл-Фәхр» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татарское «богоискательство» и пророческий ислам. К., 2003; Ислам в Татарстане в 1990-е годы. К., 2005; Хадж и умра: путеводитель по Мекке и Медине. К., 2007.

*А.В.Климин.*

**ЯГЪФӘ́РОВ** Әнвәр Ризван улы (11.11.1926, Бөгелмә кантоны, Чишмә а. — 19.6.1972, Казан), адм.-хуҗалык эшлеклесе. КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1960), Казан төзелеш инженерлары ин-тын (1969) тәмамлый. 1951–52 елларда КПССның Бөгелмә район ком-ты инструкторы, 1956–58 дә Баулы район ком-ты секретаре. 1952–53 тә КПССның Бөгелмә шәһәр ком-тының бүлек мөдире, 1958–66 да 1 нче секретаре. 1966 дан ТАССР МС рәисе урынбасары. 1959 дан ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. *Е.Б.Долгов.*

**ЯГЪФӘ́РОВ** Мәхмүт Шәрәфетдин улы (3.7.1926, Тәтеш кантоны Чирмешән а. — 31.3.2013, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (1988). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1952), РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли (1952–2004), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1987 дән). Хезмәтләре җылылык физикасына, термохимиягә, органик һәм югары молекуляр кушылмалар термодинамикасына карый. Я. динамик калориметрия (сканерлаучы калориметрия) алымын эшли. Полимерларда икенчел кристаллашу күренешен ача, полимер сәнәгате өчен мөһим гамәли әһәмияткә ия булган бу процессның кинетикасын һәм механизмын тикшерә. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1957). Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике 1 дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз ордены, 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены медале һ.б. медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фаза с кристаллическими и аморфными свойствами в полимерах. М., 1985; Новое представление о вторичной кристаллизации в полимерах. М., 1986; О природе вторичной кристаллизации в полимерах // Высокомолекулярные соединения. 1988. Т. 30, № 1.

**ЯГЪФӘ́РОВ** Рәшит Фәйзрахман улы (6.2.1946, Пермь өлкәсенең Барда р-ны Күчтәнти а. – 25.8.2008, Казан, туган авылында җирләнә), фольклорчы, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), Пермь өлкәсенең Барда авылында: «Таң» г-тасында бүлек мөдире, «Таң йолдызы» әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе. 1973 елдан Казанда. 1977 дән СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1988 дән Казан пед. ин-тында. 1990 нан Татарстан укытучылар белемен күтәрү ин-тында (2005 тән ТРның Мәгарифне үстерү ин-ты) татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире. 1992 дән «Мирас» ж-лы редакциясендә бүлек мөдире. 1993 тән Бөтентатар иҗтимагый үзәге вице-президенты, бер үк вакытта Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты рәисе киңәшчесе. 1995 тән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында. «Татар балалар фольклоры» (1998), «Бәетләр» (2000), «Мөнәҗәтләр» (2000), «Татар халык уеннары» (2002) фольклор җыентыкларын төзүче. «Тулпарлар» (1996), «Тулпар моңы» (2006), «Сагынылды» (2011) һ.б. шигырь җыентыклары авторы.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**ЯГЪФӘ́РОВ** Сабит Фатих улы (1.1.1935, БАССРның Яңавыл р-ны Байгуҗа а. — 12.6. 1981, шунда ук), нефть скважиналарын бораулау мастеры, Соц. Хезмәт Герое (1975). Саратов политехникумын тәмамлый (1975). Хезмәт эшчәнлеген 1951 елда Әгерҗе тимер юл депосында паровозлар ремонтлаучы слесарь булып башлый. 1957–64 тә «Башвостокнефтеразведка» трестының геол.-тикшерену партиясендә бораулаучы. 1964–81 дә Урай, Нижневартовск бораулау эшләре идарәләрендә, «Баштөмәннефтьгаз» («Главтюменьнефтегаз») трестының 3 нче Шаимск бораулау конторасында бораулау мастеры. Шаимск һәм Самотлорск нефть ятмаларын үзләштерүдә, алдынгы технологияләр һәм техниканы гамәлгә кертүдә катнаша. Я. бригадасы трестта иң яхшылардан була. Герой исеме 9 нчы бишьеллык (1971–75) планнарын үтәгәндә ирешкән югары җитештерү күрсәткечләре өчен бирелә. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. СССРның мактаулы нефтьчесе (1971). Урай шәһәренең мактаулы гражданы.

*Әд.:* Х а л и к о в М.С., С а ф а р о в М.А. Татары: Воины, труженики, патриоты. М., 2006.

*М.Җ.Гаитов.*

**ЯГЪФӘ́РОВ** Юныс Нәби улы (28.2.1925, Чаллы кантоны Иштирәк а. — 4.6.1994, Бөгелмә ш.), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1984). Лубян урман техникумын (1953), Казан а.х. ин-тын (1968) тәмамлый. 1941 елдан Биклән урман хуҗалыгында урманчы, 1951 дән Минзәлә урман хуҗалыгында директор. 1954 тән КПССның Минзәлә район ком-ты секретаре, 1957 дән башкарма ком-ты рәисе урынбасары, бер үк вакытта Минзәлә р-ны а.х. буенча район инспекциясе башлыгы, 1961дән Бөгелмә терр. колхоз-совхоз идарәсе башлыгы урынбасары, 1963–94 тә дәүләт «Птицевод» нәселле кошчылык з-ды директоры. Я. җитәкчелек иткәндә хуҗалыкта барлык җитештерү биналары реконструкцияләнә (кошларны читлекләргә күчерү), 188 фатир, 7 торак йорт, мәдәният йорты, балалар бакчасы, контора һәм башка җитештерү, соц.-мәдәни һәм көнкүреш объектлары булган посёлок төзелә. Һәр тавыкның йомырка салучанлыгы 190 данәдән 276 га кадәр арта. Һәр сыердан уртача еллык савым 5 мең *кг* тәшкил итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ЯГЪФӘ́РОВ** Якуб (? — 1756–57 дән соң), Оренбург сәүдәгәре, Һиндстанга барган кәрванда катнаша. 1751 елда 5 кешедән (Н.*Сәфәров*, И.*Бикмөхәммәтов*) торган сәүдә кәрваны составында Оренбургтан Бохарага юл тота. Россия хакимиятләре дипломатик максат б-н Һиндстанга барырга күрсәтмә биргәннән соң, Я. һәм аның юлдашлары сәфәрләрен Әфганстан, Иран, Гыйрак җирләре аша дәвам иттерәләр. 1756–57 дә Я. һәм Бикмөхәммәтов Дәһли шәһәренә барып җитәләр, кире кайтканда, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренә кереп чыгалар. Я. Димәшкъ шәһәрендә авырудан вафат була.

*Әд.:* У с м а н о в М.А. Записки Исмаила Бекмухамедова о его путешествии в Индию // Ближний и Средний Восток. М., 1967.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ЯГЪФӘ́РОВ** Яфәс Җәгъфәр улы (28.10.1976, Пенза өлкәсенең Кузнецк р-ны Татар Кынадысы а. – 6.3.2000, шунда ук җирләнә), РФ Герое (7.7.2000, үлгәннән соң), лейтенант. РФ Эчке эшләр министрлыгының Саратов эчке гаскәрләр ин-тын тәмамлый (1999). 1995 елдан РФ Эчке эшләр министрлыгының эчке гаскәрләрендә, «Росич» махсус максаттагы отрядта хезмәт итә. 2000 нең мартында Чечен Респ-касының Урус-Мартан районы Комсомольское авылы өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: штурм вакытында Я. төркеме авылга бәреп керә һәм терәк пунктны яулап ала. Бернichә сәгать сугышчылар кораллы төркем әгъзаларына каршы тигезсез оборона сугышы алып баралар. Я. шәхсән дошманның бернichә сугышчысын юк итә, ут эченнән яраланган гранатомётчыны алып чыга, яралана, әмма сугышуын дәвам итә. Төркемнең үз гаскәрләре янына ыргылышы вакытында ут ноктасын бастыра, снайпер тарафыннан үтерелә. Медаль б-н бүләкләнә. Я. укыган мәктәпкә аның исеме бирелә. *М.З.Хәбибуллин.*

**ЯГЪФӘ́РОВА** Гүзәл Габдулла кызы (1.4.1945, БАССРның Аургазы р-ны Талбазы а.), микробиолог, биол. фән. д-ры (1994), проф. (1995), БРның атказ. фән эшлеклесе (1998). 1970 елда Бөре пед. ин-тын (БАССР) тәмамлый. 1971 дән Уфа нефть ин-тында (1994 тән — Уфа нефть техникасы ун-ты), гамәли экология каф. мөдире (2004 тән). Хезмәтләре әйләнә-тирә мохитне экотоксиннар-

дан саклауга, ресурс һәм энергия саклаучы технологияләргә карый. Я. туфракны һәм суны нефтьтән һәм нефть продуктларыннан чистарту өчен «Родотрин» биопрепаратын сәнәгый җитештерү технологиясен эшли. Уйлап табуга 25 патенты бар. РФнең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2000).

Х е з м.: Экологическая биотехнология в нефтегазодобывающей и нефтеперерабатывающей промышленности. Уфа, 2001; Микроорганизмы и окружающая среда. Уфа, 2005 (автордаш); Инженерная экология в нефтегазовом комплексе. Уфа, 2007 (автордаш).

**ЯГЪФӘ́РОВА** Дамира Садыйк кызы (26.7.1939, Кукмара р-ны Кәчимир а.), педагог, пед. фән. д-ры (1992), проф.(1992), ТРның атказ. укытучысы (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). 1965 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1956 дан Кукмара посёлогының 2 нче мәктәбендә өлкән пионервожатый, 1959 дан ВЛКСМның Кукмара район ком-ты 2 нче секретаре, 1961 дән КПССның Кукмара район ком-ты инструкторы, 1964 тән бөтенсоюз «Артек» пионерлагерендә, 1967 дән Алабуга пед. ин-тының пед. кафедрасында, 1976–87 дә каф. мөдире. 1996–2009 да Әлмәт муниципаль ин-ты (хәзер Әлмәт муниципаль хезмәтләр ин-ты) ректоры. Хезмәтләре укытучылар әзерләү, халык мәгарифе тарихы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Российские университеты: прошлое, настоящее и будущее. Наб. Челны, 2003.

**ЯДЕГӘ́Р** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 27 *км* төньяк-көнбатыштарак, Юраш елгасы (Вятка бассейны) буенда. 2010 елда 33 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты, китапханә. 1800 еллар тирәсендә Иске Юраш авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ядегәр Пүчинкәсе исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 265 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда. 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән — Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 38, 1887 дә — 139, 1905 тә — 180, 1920 дә — 166, 1926 да — 191, 1938 дә — 224, 1949 да — 218, 1958 дә — 192, 1970 тә — 190, 1979 да — 128, 1989 да — 72, 2002 дә — 51 кеше.

**ЯДЕГӘ́Р** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 29 *км* көнбатыштарак, Балтач — Кукмара автомобиль юлы буенда. 2010 елда 497 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән Ядегәр исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Деревня по речке Едыгер булarak билгеле. 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, курыс төшерү-мунчала ясау, баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөздә Я.дә 2 мәчет, 1 мәдрәсә, 2 су тегермәне, 6 вак-төяк-ләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1452,1 тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда. 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Арча, 1928 дән — Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 250 ир-ат; 1859 да — 1043, 1897 дә — 1130, 1908 дә — 1345, 1920 дә — 1201, 1926 да — 1094, 1938 дә — 1018, 1949 да — 1093, 1958 дә — 610, 1970 тә — 497, 1979 да — 459, 1989 да — 487, 2002 дә — 546 кеше.

**ЯДЕГӘ́Р БӘК** (? — 1563), Себер ханлыгы идарәчесе (1520 еллардан). *Бикбулат* бәк б-н бергә идарә итә. Нугай Урдасы б-н аркадашлык сәясәте йөртә. Казан яуланганнан соң (1552), Идел буенда Мәскәү патшасының йогынтысы нәтиҗәсендә һәм *Кучум хан* Иртеш елгасы буйларына бәреп кергәч, Я.б. Мәскәү б-н мөнәсәбәтләрне яхшырту юлларын эзләргә мәҗбүр була. 1555 елда ул, Себер ханлыгын Рус дәүләте яклавына алуны һәм даими ясак билгеләүне сорап, Мәскәүгә илчеләр юллый. Иван IV үз наместнигын һәм ясак җыючыны җибәрә, ләкин Я.б. үзара килешү шартларын үтәргә ашыкмый. 1557 дә нугай морзасы Исмәгыйль йогынтысында үзен кабат Иван IV вассалы дип таный, Мәскәүгә илчеләр һәм түлисе ясакны җибәрә. 1563 тә Күчүм хан гаскәре Бикбулат бәк б-н Я.б. көчләре Себер ханлыгында хакимиятне ирешү өчен көрәшкән Күчүм хан гаскәре тарафыннан җиңелә; икесе дә әсир төшә һәм җәзалап үтерелә.

*Әд.:* М и л л е р Г.Ф. История Сибири. М.–Л., 1937. Т. 1; История Сибири. Л., 1968. Т. 1.

*И.Л.Измайлов.*

**ЯДЕГӘ́Р МӨХӘММӘ́Д** (? — 26.8.1565, Мәскәү), Казан ханы (1552). Әстерхан ханы *Касыймның* улы. 1542–50 елларда Я.М. рус хезмәтендә була. 1550 дә рус гаскәренең Казанга явында катнаша. Шул ук елда хезмәтен калдырып Нугай Урдасына китә. 1552 дә сәед *Колшәриф* һәм *Чапкын бәк Отыч* улы башлангычы б-н Казан хөкүмәте тарафыннан Казан тәхетенә чакырыла. 1552 дә Казанны Иван IV гаскәрләреннән саклау җитәкчеләреннән берсе (к. *Казанның яулап алынуы*); әсирлеккә эләгеп Мәскәүгә озатыла. 1553 тә чукындырылып, Симеон исеме кушыла. Чыганакларда язылганча, «патша һәм бөек кенәз Симеон патшаны ярлыкады, аңа утар бирде... аны әсир кебек түгел, ә бәлки, аның дәрәҗәсенә карап, патша һәм патша улы кебек тотты». Я.М. аксөяк рус түрәсе кызы Мария Андреевна Кутузовага өйләнә. Чудово монастыренда (Мәскәү) җирләнә.

*Әд.:* Х у д я к о в М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

**«ЯДКӘРНАМӘ́»** (يادكارنامه; «Истәлек китабы»), Алтын Урда дәвере төрки-татар шагыйрьләре әсәрләренең кульязма җыентыгы. 14 йөздән соң мәмлүкләр Мисырында Әбү-л бине Кадыйр тарафыннан төзелә. Кульязманы Урта Азиягә 18 йөздә хаҗиларның берсе алып кайта, фәнгә 1965 елдан билгеле. Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасы һәм берничә шигыре, Әхмәд Үргәнчи, Тугълы Хуҗа һәм Мәүләна Исхакның шигырьләре урнаштырылган. «Я.»не үзбәк һәм татар галимнәре Н.Дәүранов һәм Х.Миңнегулов өйрәнә. Кульязма Үзбәкстан ФАнең Шәрекъне өйрәнү ин-тында саклана (Ташкент ш.).

*Әд.:* С а р а и С. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

**Я́ДРИН ӨЯЗЕ́**, *Казан губернасында* адм.-терр. берәмлек (1708 елдан). Үзәге — Ядрин шәһәре (1590 да Сура елгасының сул ягында кальга буларак нигезләнә; 1781 дән өяз шәһәре). Я.ө. 1590 елларда Ядрин тирәсендәге җирләрдән формалаша. 1708 дән — Казан губернасының состав өлеше, 1714–17 дә — Түбән Новгород, 1717–19 да — янә Казан губернасында. 1719 да Түбән Новгород губернасының Алатырь провинциясенә теркәлә. 1779 да кабат Казан губернасы (1781 — 96 да — Казан наместниклыгы) составында. Төньяк-көнбатышта — Түбән Новгород губернасының Васильсурск, төньякта — Казан губернасының Козьмодемьянск, төньяк-көнчыгышта — Чабаксар, көнчыгышта — Цивильск өязләре, көньяк-көнчыгышта — Сембер губернасының Буа, көньякта — Алатырь, көнбатышта Кормыш өязләре б-н чиктәш була. Территориясеннән Сура, Олы һәм Кече Цивиль, Олы Сорма елгалары ага. Өязнең мәйданы 2,9 мең кв. чакрым. Халкы 161,2 мең кеше, шулардан 93,8% ы чуашлар, 6,2% ы руслар (1901) тәшкил итә. Адм. яктан Я.ө. 13 өлешкә: Аликово, Асакасы, Балдаево, Малояушево, Норусово, Тойсин, Тораево, Уби, Хочашево, Чебаево, Чувашская-Сорма, Шуматово, Ядрин волостьларына бүленә. Халкы игенчелек, өлешчә кәсепчелек (йон тетү, итек тегү, көпчәк ясау, такта яру) б-н шөгыльләнә. Я.ө.ндә аракы куу һәм май язу з-длары, ш.у. 827 вак сәнәгать оешмалары эшли (1901). Өяздә 131 мәктәп була. 1920 дә Я.ө. Чуаш автономияле өлкәсенә (1925 тә Чуаш АССР итеп үзгәртелә) кертелә. 1927 дә Чуаш АССРда районнарга бүленеш кертелү сәбәпле, Я.ө. бетерелә.

*Әд.:* С п а с с к и й Н.А. Очерки по родиноведению: Казанская губерния. К., 1912; Краткая чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2001.



**ЯЗ**, ел фасылы, аерым бер билгеләр (астрономик, климатик, синоптик, фенологик һ.б.) буенча билгеләнә. Астрономиядә төньяк ярымшарда Я.га язгы көн-төн тигезлеге б-н (20–21 март) җәйге кояш торгынлыгы көне (21–22 июнь) арасындагы вакытны кертәләр. 1 марттан 31 майга кадәрге чор календарь Я. дип санала. Климатик сезон буларак, Я. кыштан җәйгә күчү вакыты, һава темп-расының күтәрелүе б-н характерлана. Я. башы дип һаваның уртача тәүлеклек темп-расы 0 °С аша тотрыклы узу, (ТР терр-ясендә уртача 5 һәм 10 апрель аралыгында күзәтелә) яки тотрыклы кар капламы эри башлау (уртача 6–16 апрель) датасы алына. Климатик Я.ның тәмамлануы һаваның уртача тәүлеклек темп-расы 15 °С аша узу датасы (27 май – 2 июнь) яки һавада язгы кырауларның тәмамлануы (7–26 май) б-н билгеләнә. Шулай итеп, ТРда Я. уртача 2 ай тирәсе дәвам итә. Уртача айлык темп-ра апрельдә 2,5–4,5 °С тан (абс. макс. 29–30°С, абс. мин. –28 дән -36°С ка кадәр) майда 11–13 °С ка кадәр (абс. макс. 32–35 °С, абс. мин. –6 дан –10 °С ка кадәр). Атмосфера явым-төшемнәренең уртача күләме майда — 35–45 *мм*, сезонга — 65–75 *мм*. Язгы чор өчен 10 елга уртача 3–4 тапкыр күзәтелүче һәм еш кына коры җилләр б-н бергә билгеләнүче атм. *корылыгы*, ш.у. *кырау*, ә аерым елларда боз яву, *су басу* куркынычы хас.

Я. — табигатьнең җанлану чоры. Кара каргалар кайта («кара карга килгәч, бер айдан кар китәр»), март ахыры — апрель башында сыерчыклар һәм тургайлар килә. Урман кошлары — кызылтүш, миләш чыпчыклары һәм язгы ташу хәбәрчеләре — чәберчек кошлар күренә башлый. Очлы яфраклы өрәңге һәм сөялле каен агачларында сут йөри башлый, усак һәм кабар агачларының кабыгы яшелләнә. Ак зирекнең орлыклары коела, кызыл талның ак йомшак алкалары ачыла. Беренче үги ана яфрагы, җилдәк, кукебаш, сәрдәнә, зибык уты, каз юасы чәчәкләре күренә. Балыклар сай сулыкларга җыела. Эт шомырты күбәләге һәм кайгылы күбәләк очып чыгалар, камкалар йокыдан уяна. Март ахырында бүре, куян, бурсык, төлкеләрнең балалары туа. Я. ахырында шомырт (бу чорда еш кына яңадан суытып ала); иң соңыннан балан, юкә, имән чәчәк ата.

*Әд.:* Климат Татарской АССР. К., 1983.

*М.А.Верещагин.*



**Яз.** 1. Иделдә боз өентеләре; 2. Кырларда соңгы карлар; 3. Күл янында кардан ачылган урыннар (Васильево штп янында); 4. Ачык йокы үләне (умырзая); 5. Алмагачлар чәчәк ата (Балык Бистәсе районы «Масловский» совхозы).

**«ЯЗ»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби, юмористик һәм сатирик рәсемле журнал. 1907 елның мартында Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 2 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Й.Мозаффаров. Журнал халыкларның тигез хокуклыгы, татарларның социаль хәлен яхшырту мәсьәләләрен алга сөрә. 1 нче һәм 2 нче Дәүләт Думалары, мөселман депутатлар эшен яктырта, Россия империясенең мөселманнарга кагылышлы законнарына аңлатма бирә. Мөселман мәгарифе реформалары турында фикер алышу яктыртыла. Әдәби әсәрләр, ш.и. Ш.Абызгилдинның сәяси шигырьләре, Л.Толстой әсәрләреннән өзекләр басыла. «Я.» битләрендә эшчәнлекләре турында кыскача мәгълүмат б-н күренекле сәясәт, мәдәният, әдәбият эшлеклеләре портретлары урнаштырыла, Россиянең зур түрәләренә карикатуралар бирелә.



«Яз» журналы.

*Әд.:* Г ы й м а д и е в Ү. Сатира коралы белән. К., 1977.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ЯЗ ГӨМБӘСЕ́** (Pleurotus), рядовка семьялыгыннан гөмбәләр ыругы. ТР терр-ясендә гади Я.г. (P.ostreatus), көзге Я.г. (P.salignus) киң таралган. Зур төркемнәр хасил итәләр. Үзагачта, майдан көзге суыкларга кадәр үсәләр. Эшләпәсе юка читле, кабарынкы, яшь гөмбәләрнең эшләпә чите аска таба бөгелеп тора, диаметры 5–12 *см*, соргылт-сары, коңгырт яки кара коңгырт төстә. Пластинкасы сабына таба кими барган кебек, ак яки саргылт. Споралы порошогы ак. Сабы кыска (озынлыгы 4 *см* га кадәр), цилиндрсыман (юанлыгы 2 *см* га кадәр), төбендә аз гына төкчәле; кайвакыт сабы юк һәм үрчү өлеше субстратка яны б-н берегә. Йомшагы ак, көпшәк, хуш исле. Ашарга яраклы. Яңа җыйган, тозланган һәм маринадланган килеш кулланыла. ТРда «Весенний», «Майский» һ.б. с-зларда үстерәләр.

**ЯЗГЫ́ БОДА́Й**, к. *Бодай.*

**ЯЗГЫ́ КУЛЬТУ́РАЛАР**, а.х. үсемлекләре, яз көне чәчеләләр һәм шул елны уңыш бирәләр. Кыска вакытта яровойлашалар, аны язгы чорда 3–8 °С та, кайберләре 7–12 °С та узарга өлгерәләр. Я.к.га төрле а.х. үсемлекләре керә: бөртеклеләр (ашлык) — сабан бодае, арпа, солы; ярма культуралары — тары, карабодай, кукуруз; бөртекле-кузаклылар — борчак, вика, фасоль, ясмык, соя; май бирә торган үсемлекләр — көнбагыш, рапс; яшелчәләр — кыяр, ташкабак; бүлбетамыразыклар — бәрәңге, чөгендер; силос культуралары — ку-

куруз, шикәр соргосы; тамыразык үләннәр — вика, судан үләне, майлы торма. Я.к. хәзерге Татарстан терр-ясендә бакча һәм *игенчелекнең* сөрүле системасы вакытыннан ук а.х. культураларыннан башлангыч ала. Бәрәңге — 18 йөз башыннан, шикәр чөгендере — 1950 еллар ахырыннан, кукуруз — 1960 еллардан, рапс 1980 еллардан үстерелә. 2012 дә Я.к. 2236,5 мең *га*, ш.и. бөртеклеләр — 1232,7, техник культуралар — 306,7, бәрәңге — 80,5, яшелчә — 11,7, терлек азыгы культуралары — 539,4, шулардан кукуруз 178,3 мең *га* мәйданны били. *И.Н.Афанасьев.*

**ЯЗИКӘ́Ү** авылы, Сарман р-нында, Сарман р-нынннан 16 *км* төньяктарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. 1680 нән Красная Дуброва исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Михайловка, Дубровка, Стадухино буларак билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, ипи пешерү һәм олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.дә волость идарәсе урнаша; Михаил-Архангел чиркәве (1881 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе, су тегермәне, тимерче алачыгы, ашлык саклау-сату кибете, 1 шәраб һәм 4 бакалея кибете, Стахеев кибете, сырахәнә була; дүшәмбе базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1525 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Язикәү волостенда.1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 1022, 1897 дә — 928, 1906 да — 1116, 1920 дә — 946, 1926 да — 751, 1949 да — 346, 1958 дә — 221, 1970 тә — 89, 1979 да — 27, 1989 да — 7, 2002 дә — 2 кеше.

**ЯЗЛЫ́ АРТА́Ш** (Тарлау) авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 17 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 122 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән Азларташ Пүчинкәсе исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тарлау исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысыннан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, такта яру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 713,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 34 ир-ат; 1859 да — 156, 1897 дә — 365, 1908 дә — 401, 1920 дә — 458, 1938 дә — 378, 1949 да — 251, 1970 тә — 416, 1979 да — 192, 1989 да — 166, 2002 дә — 158 кеше.

**ЯЗУ́ МАШИНАСЫ́**, хәрефләр, цифрлар һ.б. билгеләрне басучы механизм клавиатурасы ярдәмендә эзлекле рәвештә бастыру ысулы б-н текстлар язу өчен җайланма. Гарәп графикасы нигезендәге татар язуы өчен беренче Я.м.н Ә.Г.*Шәехгали* (1923) конструкцияли. Аның каретканы уңнан сулга билгеле аралыкларга (хәреф зурлыгына карап) автоматик рәвештә йөртү өчен җайланмасы була; машинка *гарәп язуының* үзенчәлекләренә: баш хәрефләр юклыгына, сүздәге урынына һәм киңлегенә карап, хәрефләрнең 4 төрле кушылып язылуына көйләнеп ясала. Шәехгалинең уйлап табуы ТАССР ҮБК һәм ХКСның «Татар телен респ-каның совет учреждениеләрендә эш теле буларак гамәлгә кертү турында» 1921 ел 25 июнь Декретын тормышка ашыру мөмкинлеге бирә. 1925 нең гыйнварында ТАССР нәшрият һәм матбугат комб-ты каршында «Татязмаш» остаханәсе (җитәкчесе Ә.Г.Шәехгали) ачыла. Анда чит илдән кергән Я.м. нигезендә иске һәм яңа татар орфографиясе алфавитында кулланылган хәрефле, рус-татар клавиатуралы, яңа төрки (латиница нигезендәге), мари, чуаш, удмурт (кириллица нигезендә) шрифтлары куелган машиналар җитештерелә; күп кенә башка төрки һәм гарәп алфавитларында кулланылган билге һәм хәрефле Я.м. чыгарыла. Остаханә респ-каның үзәк, кантон, волость учреждениеләрен Я.м. б-н тәэмин итә, ш.у. Урта Азия, Төньяк Кавказ төбәкләреннән, Кытайдан, Әфганстаннан, Ираннан, Ливиядән, Төньяк Африка илләреннән һ.б.дан заказлар кабул итә.

1929 да латин шрифты нигезендә татар алфавиты — *яңалиф* кертелгәч, гарәп графикалы Я.м.н җитештерү туктатыла. Латин шрифтлы «Яңалиф» машинкасының («Janalif») беренче үрнәкләре ш.у. чит илләрдән кертелгән машиналар нигезендә ясала. 1929 ның октябрендә Ә.Г.Шәехгали башкарган хисаплаулар һәм техник документация буенча слесарь-техниклар Г.А.*Елизаров* һәм Н.П.Тихонов, илдә җитештерелгән материаллар нигезендә ясалган детальләр кулланып, Я.м. эшләп чыгаралар. СССР Эшче-крәстиян инспекциясе халык комис-ты каршындагы Идарә техникасы ин-тында экспертиза үткәрелгәннән соң, Казанда Я.м.н күпләп җитештерү максатка ярашлы дип табыла. 1930 да — «Татязмаш» остаханәсе базасында Казан язу машиналары фабрикасы, 1931 дә Казан язу машиналары з-ды (к. «*Терминал*») төзелә. «Яңалиф» Я.м.н җитештерү, билгеле дәрәҗәдә камилләштерелеп, татар язуы 1939 да *кириллицага* күчерелгәнгә кадәр дәвам итә. 1940 та рус һәм татар телләрендә басу өчен «Прогресс» Я.м. эшләнә.

Чыг.: Пат. № 8434 (СССР). Описание приспособления для передвижения каретки пишущих машин для татарского письма на различные расстояния, в зависимости от ширины букв. Заяв. 11.01.1927. Опубл. 30.03.1927, Бюл. № B41J19/98; Пат. № 3383 (СССР). Описание пишущей машины для татарского письма. Заяв. 09.08.1924. Опубл. 31.08.1927, Бюл. №B41J1/04.

*Әд.:* Татарча язу машиналары // Безнең юл. 1925. № 2; Уткин М. Люди одной судьбы: Очерки истории Казанского ордена Трудового Красного Знамени завода пишущих устройств и о его людях. К., 1991; Султанбеков Б. Талант инженера и руки мастера // Респ. Татарстан. 1995. 15 июля.

*М.Ш.Бәдретдинова, Г.Х.Галимуллина.*

**ЯЗЫ́КОВНЫҢ БОЛГА́Р БАССЕ́ЙНЫ**, Идел елгасының Самара Дугасы (Идел борылышы) б-н Кама елгасының түбән агымы арасындагы иңкүлекле сулъяк яры исеме. Сембер геологы П.М.Языков фикеренчә, бассейн борынгы Каспийның комсу-балчыксыл утырмаларыннан (постплиоцен — дүртенчел чор) барлыкка килгән. Хәзерге күзаллаулар буенча, 350 *м* га кадәр калынлыктагы неоген һәм дүртенчел чор системаларының елга һәм күл утырмаларыннан тора. Бары тик неоген чоры катламының югары өлешендә генә диңгез утырмаларының бик калын булмаган (10–15 *м*) катламы күзәтелә. Бассейнны билгеләүдә бу катламдагы тозлы сулы Арал-Каспий кабырчык табылдыклары нигез булып хезмәт итә, исеме борынгы Болгар дәүләте башкаласы б-н бәйле. Бассейн турында беренче мәгълүматларны П.М.Языков Р.И.Мурчисонга хат (1841) рәвешендә тасвирлап җибәрә.

*Әд.:* Мурчисон Р.И., Вернейль Э., Кейзерлинг Г.А. Геологическое описание Европейской России и хребта Уральского. СПб., 1849. Ч. 1; Миртова А.В. Следы солоновато-водной фации Акчагыла в пределах так называемого Болгарского бассейна Языкова // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1927. Т. 51, вып. 5.

*А.П.Дедков.*

**ЯЗЫ́КОВО** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 43 *км* көньяк-көнбатыштарак, Актай елгасы буенда. 2010 елда 73 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1710 нан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 369,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ромодан волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 57 ир-ат; 1859 да — 194, 1897 дә — 199, 1908 дә — 267, 1920 дә — 267, 1926 дә — 217, 1938 дә — 208, 1949 да — 190, 1958 дә — 175, 1970 тә — 169, 1979 да — 115, 1989 да — 83, 2002 дә — 83 кеше.

**ЯЗЫ́НИН** Иван Лаврентьевич (25.11.1928, Кызыл Чаллы а., хәзер Чаллы шәһәренә керә — 10.12.1977, Казан), график, китап бизәүче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1968). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1951), Эстония ССР Дәүләт сәнгать ин-тын (Таллин,1957) тәмамлый. 1958 елдан Казанда яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1962). Китап бизәү буенча әйдәп баручы рәссамнарның берсе, танылган станлы графика остасы, портрет, пейзаж, көнкүреш, анималистик һәм тарихи жанрларда эшли. Композицияләрне оригиналь техникада да (күмер, карандаш, акварель, гуашь), гравюрада да (офорт, акватинта, литография, линогравюра) ясый. Я.ның төсләр б-н эшләү таланты башлангыч этюд-пейзажларында ук чагылыш таба.

Я. китап графикасы үсешенә аеруча зур өлеш кертә. 1958 дән Татарстан китап нәш-








И.Л. Язынин. 1. «Батырлар килә». С.Злобинның «Степан Разин» китабына шмуцтитул. Кәгазь. Акватинта. 1957. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Иделдә». Кәгазь. Акватинта. 1950 еллар; 3. «Кабул ит, Ватан!» плакаты. 1977.

риятында эшли; татар, рус һәм чит ил язучыларының 400 дән артык китабын бизи. «Идел», «Ялкын» ж-лларының тышлык эскизларын ясый. Ю.Малевинскийның «Андрей хикәяләре» («Андрейкины рассказы»), Н.Некрасовның «Үле күл» («Мёртвое озеро») (икесе дә — 1958), М.Җәлилнең «Джим» (1960), Р.Кутуйның «Малайлар» («Мальчишки», 1961), М.Фәйзуллинаның «Гөлнара мәктәпкә бара» (1963), К.Чуковскийның «Доктор Айболит» (1973) китапларының бизәлеш авторы. Төсле линогравюра техникасында зур кызыксыну б-н эшли (М.Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» («Моабитская тетрадь», 1963) җыентыгына һ.б.). Р.Вәлитова, С.Вагыйзовның Я. бизәгән «Әлифба»сы (1963) берничә тапкыр бастырыла һәм бөтенроссия, бөтенсоюз китап конкурсларында дипломнар б-н бүләкләнә (1966). Н.Бакыева, М.Җиһаншина, Л.Панькинаның «Музыкаль әлифба»сы («Музыкальная азбука», 1970) 1971 дә Бөтенроссия китап конкурсында диплома, Н.Хәсәновның «Рус теле дәреслеге» («Учебник русского языка», 1970) 1975 тә Бөтенроссия китап сәнгате конкурсында 2 нче дәрәҗә дипломга лаек була. 1960 та А.Салминның «Иделдә давыл» («Буря на Волге») романына илл. ясаудан башланган эш төсле 7 линогравюраны берләштерүче «Иделдә гражданнар сугышы» сериясенә әверелә. Ул 60 еллар Казан графикасында иң билгеле күренешләрнең берсе була. Анда тарихи чынбарлыкны чагылдыру омтылышы образларның тыгызлыгы һәм калку сурәтләнеше б-н тәңгәлләшә. Линогравюрага хас кырыс, гомумиләштерелгән сәнгатьчә тасвир нечкә нюанслы төсләр куелыгы б-н йомшартыла. Бу рәссам тарафыннан кулланылган күчеш буяу б-н каплау техникасы ярдәмендә күчеш бирүче төсләр аша башкарыла. 1960–70 елларда Я. күмер, монотопия б-н станлы рәсемнәр циклы ясый. Аның кульминациясен авторлык техникасында — рельефлы киселгән катыргыда пастель б-н ясалган «Өч гасыр аша» (1969) сериясе тәшкил итә.

Казан агитплакат остаханәсендә эшләү Я. иҗат эшчәнлегенең мөһим өлеше булып тора (1961 дән). Ул, Казан рәссамнарыннан беренче булып, совет тарихының төп моментларын чагылдыручы, күбесенә үзенең шигъри юллары язылган сәяси, агитация плакатлары циклын эшли: «Ант итәбез!» (1967), «Лаек бул!» (1975), «КАМАЗ — елъязма» (1977) һ.б.

Респ-ка күргәзмәләрендә (1957 дән); төбәкара — Идел буе рәссамнар күргәзмәләрендә (1958–80); бөтенроссия — «Бөек Октябрьнең 40 еллыгы» (1957), балалар китаплары (1965), «Совет Россиясе-4» (Мәскәү, 1970), бөтенсоюз — офорт, эстамп (икесе дә — Ленинград, 1958), сәяси плакат (1963, 1967), балалар китабы (Мәскәү, 1973) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1991–92 (Чаллы ш.), 2003 тә (Казан) үткәрелә. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Чаллы, Әлмәт картиналар галереяларында саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Иван Лаврентьевич Язынин, 1928–1977: Станковая и книжная графика, плакат, живопись: Каталог выставки. К., 2003.

*О.Л.Улемнова.*

**ЯКА́ ЧЫЛБЫРЫ́**, борынгы зәркән эшләнмә, татар хатын-кыз костюмы комплексына кергән муен-күкрәк бизәмәсе. Төрле яшьтәге һәм төрле катлауга караган шәһәр һәм авыл хатын-кызлары бәйрәм вакытында тага. Ул парлы яка каптырмасыннан һәм күкрәк уртасына кадәр төшеп торган фигуралы җиз тәңкәле, очында эре асылмасы булган чылбырлардан тора. Бер яктан ыргак икенче яктан элмәк тагылган ике баштан беркетелүле яка — укалы утыртма якага тегеп куела һәм күлмәк якасы өстеннән киелә. Каптырмаларның асылмаларсыз үрнәкләре дә очрый. Ул түгәрәк, турыпочмаклык (ян-яклары түкранбаш яфрагы мотивлары б-н тулыландырыла), йөрәк, яфрак рәвешендә яки катлаулы формада була. Каптырма капкачы чүкеп һәм үзәгенә төсле һәм кыйммәтле ташлар куеп бизәлә, контуры кечерәк түгәрәк ташлар б-н каймалана. Җиз тәңкәләр, гадәттә, яфрак рәвешендә була һәм бөҗра ярдәмендә тоташтырыла. Асылмалар, нигездә, яфрак рәвешендә яки түгәрәк формасында булып, төрле асылташлар б-н бизәлә. Я.ч. алтыннан яки көмештән (еш кына алтын йөгертелгән) ясала: кызлар өчен 1–3, хатыннар өчен 5–9 чылбырдан тезелә. 5 чылбырдан торганы аеруча киң таралыш ала. Кыйммәтле нөсхәләрдә төп элементлар челтәрле яссы һәм күпертмә җепкыр, гадирәкләре чүкеп, гравирлап яки калыплап эшләнгән үсемлек-чәчәк орнаменты б-н бизәлә, соңгысында асылмалар сыйфатында көмеш («екатерининкалар») яки гади акчалар файдаланыла. Я.ч. төрле кыйммәтле һәм ярымкыйммәтле ташлар (рубин, аметист, фирүзә, тау бәллүре, ахак) б-н инкрустацияләнә. Аның иң әүвәлге классик формалары 18 йөзнең 1 нче яртысына карый. 18 йөзнең 2 нче яртысында эшләнгәннәре матур форма һәм техник башкарылыш камиллеге б-н аерылып тора. 19 йөздә эшләнгәннәреннән аермалы буларак, аларга җепкыр бөтеркәләренең нәфислеге, бизәкләрнең чиста эшләнеше, җепкырларның тыгызлыгы хас.

Я.ч. ның килеп чыгышы бәхәсле мәсьәлә. Кайбер галимнәр аны Алабуга төбәге керә-









1. Яка чылбыры. Көмеш, алтын йөгертү, ярымасылташлар. Челтәрле һәм күпертмә җепкыр. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Милли музее; 2, 3. Яка чылбырлары. Фрагментлар. Көмеш, алтын йөгертү, фирүзә, ярымасылташлар. Күпертмә һәм челтәрле җепкыр. 19 йөз. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. Яка чылбыры. Көмеш, алтын йөгертү, фирүзә, ярымасылташлар. Челтәрле җепкыр, штамповка. 19 йөз. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

шен татарлар төркеменең 20 йөз башына кадәр сакланып калган борынгы бизәнү әйбере — муенга эленә яки күлмәк якасына беркетелә торган асылмалы чылбыр дип, кайберләре исә болгарлардан килә торган һәм Идел буе халыклары (мордва, чуаш, мари) һәм төрки халыклар (казакъ, кыргыз, төрекмән, үзбәк һ.б.) киемнәрендәге борынгы каптырма дип исәпли. 19 йөз ахырында Я.ч. кулланылыштан чыга. Челтәрле формалары хәзерге рәссам-зәркәнчеләр (С. Шәкүрова, И. Фазылҗанов һ.б.) тарафыннан файдаланыла.

*Әд.:* Поздеева Л. Старинное шейно-нагрудное украшение казанских татарок // Материалы Центр. музея ТАССР. К., 1930. № 2; Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Гаген-Торн Н. Женская одежда народов Поволжья. Чебоксары, 1960; Суслова С.В. Женские украшения казанских татар середины 19 — начала 20 вв. М., 1980; Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Татарская филигрань: в контексте генезиса и развития ювелирного искусства // Из истории татарского народного искусства. К., 1995.

*Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЯКИ́МОВ** Алексей Васильевич (1.3.1952, Сарман р-ны Шуран а.), галим зоотехник, а.х. фән. д-ры (1998), проф. (2002). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Питрәч р-нының «Кощаково» җәнлек с-зында эшли. 1978–83 елларда комсомол эшендә. 1983–86 да ТАССР А. х. министрлыгының Респ-ка хезмәтне фәнни оештыру үзәге директоры урынбасары. 1986 дан Казан вет. ин-тында; 1988 дән «Татарстан кыры» ФҖБ дә, лаб. мөдире (1996 дан); 1999 дан «Терлек азыгына өстәмәләр» Фәнни-тикшеренү үзәге ген. директоры (Казан). Хезмәтләре а.х. терлекләрен тукландыру мәсьәләләренә карый. ТР Дәүләт бүләге рапс җитештерү, эшкәртү һәм куллануның икътисади нигезләрен һәм фәнни нигезләнгән технологияләрен эшләүдә һәм киң даирәдә гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә (1997).

Хезм.: Цеолитсодержащие породы Татарстана и их применение. К., 2001 (автордаш); Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002 (автордаш).

**ЯКИ́МОВ** Николай Дмитриевич (4.7.1945, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1987), проф. (2002). 1967 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук, Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тының аналоглы модельләштерү лаб-ясе мөдире булып эшли (1981–89). 1996 дан Казан энергетика ин-тының җылылык техникасы теоретик нигезләре каф. профессоры. Хезмәтләре фильтрация теориясе һәм җир асты гидромеханикасы мәсьәләләренә, ваккуышлы мохитләрдә масса күчерүгә багышлана. Я. билгесез депрессион өслекле җир асты суларын фильтрлау, нәсызыкча фильтрация, кайтма кырый мәсьәләләр, ш.у. тоташ мохит механикасының кайбер мәсьәләләре өчен вариацияле-топологик чагыштыру теоремаларын формалаштыра һәм исбат итә; бу мәсьәләләрнең чишелүчәнлеген һәм үзлекләрен тикшерә, аларның аналитик чишелешләрен таба.

Хезм.: Исследование разрешимости задачи фильтрации в неоднородной земляной плотине // Докл. АН СССР. 1979. Т. 249, № 2; Аналитические решения задач фильтрации. Обратный метод, вариационные теоремы, оптимизация и оценки: Обзор // Изв.РАН. Механика жидкости и газа. 1998. № 2 (автордаш); Minimal advective travel time along arbitrary streamlines of porous media flows: the Fermat-Leibnitz-Bernoulli problem revisited // Journal of Hydrology. 2009. V. 375, № 3/4 (автордаш).

**ЯКИ́МОВ** Олег Алексеевич (17.3.1975, Питрәч р-ны Кощаково а.), вет. табибе, вет. фән. д-ры (2006). Казан вет. медицинасы академиясен тәмамлаганнан соң (1998), «Өстәмә азык» фәнни-тикшеренү үзәгендә (Казан) эшли. 2009 дан Казан вет. медицинасы академиясендә. Хезмәтләре а.х. терлекләре һәм җәнлекләре рационына табигый минераллар кушу мәсьәләсенә карый. Буа р-ны а.х. җитештерүендә Татарстанның үз агроминераль чималын кулланып ресурс саклаучан технологияләр кертүдә катнашканы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2003).

Хезм.: Пушное звероводство // Цеолитсодержащие породы Татарстана и их применение. К., 2001; Применение кормовых добавок в кормлении индюшат-бройлеров // Уч. зап. Казан. гос. акад. вет. медицины. 2017. Т. 230. Вып. 2 (автордаш); Продуктивность кроликов при использовании в их рационах кормовых добавок // Кролиководство и звероводство. 2017. Вып. 3 (автордаш).

**Я́КИН** Хәбибулла Хәйрулла улы (25.9.1923, хәзерге Төмән өлкәсенең Түмән р-ны Муллаш а. — 7.6.2009, Төмән ш.), Дан орденының тулы кавалеры (19.12.1944, 8.3.1945, 29.6.1945), гв. ефрейторы. Омск шәһәрендә Аксарка башлангыч мәктәбендә укытучы булып эшли. 1942 елның гыйнварыннан Кызыл Армиядә. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында: элемтә взводы телефонисты, 315 нче гв. тау-укчы полкының (1 нче гв. армиясенең 128 нче гв. тау-укчы дивизиясе) пулемёт расчёты командиры. Көнбатыш һәм 4 нче Украина фронтлары составында Ржев-Вязьма (1943), Житомир-Бердичев, Проскуров-Черновцы, Львов-Сандомир (барысы да 1944 тә) һәм Моравска-Острава (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 21 сентябре — 12 ноябрендә Борова торак пункты янындагы (Медзилаборце (Чехословакия) шәһәреннән 3,5 *км* төньяктарак) сугышларда батырлык күрсәтә: батальонның башка подразделениеләр б-н элемтәсен урнаштырып, 60 тан артык сафтан чыккан урынны төзәтә, шәхси коралы б-н дошманның 5 солдатын юк итә; 1945 нең 12–13 февралендә Елесня торак пункты (Бельско-Бяла (Польша) шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак) янындагы сугышларда, тау-урманлы урыннар булуга карамастан, артиллерия-миномёт уты астында элемтә урнаштыра, 15 ләп фашист солдатын юк итә; 1945 нең 15–16 апрелендә Гожице һәм Ухильско торак пунктлары (Рацибуж (Польша) шәһәреннән 19 — 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак) янындагы сугышларда дошманның 10 лап пехотачысын юк итә, 2 пулемёт ноктасын бастыра. Демобилизацияләнгәннән соң (1946), Төмәндә яши, пед. ин-тын тәмамлый (1961), Шыкча авылы (Төмән р-ны) мәктәбендә укытучы булып эшли. Ржев (1993) һәм Төмән (1995) шәһәрләренең мактаулы гражданы. Туган авылының бер урамы һәм Шыкча авылы мәктәбе Я. исемен йөртә. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Х.Х. Якин.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЯКО́БИЙ** Аркадий Иванович (22.9.1827, Казан — 15.4.1907, шунда ук), гигиенист, земство эшлеклесе, медицина д-ры (1860, 1863), атказ. проф. (1890). Вюрцбург ун-тын тәмамлаганнан соң — медицина д-ры (1860), Россиягә әйләнеп кайткач, Император мед.-хирургия академиясе д-ры (1863) дәрәҗәләре ала. В 1864–1907 елларда Казан ун-тында: в 1865–71 дә мәхкәмә медицинасы, 1885 тән гигиена (бүленеп: 1872–85 тә Харьков ун-тының гигиена каф. мөдире) кафедралары профессоры һәм мөдире, гомуми терапия һәм табиблек диагностикасы кафедрасы экстраординар профессоры. 1890 да Я. Халык мәгарифе министрлыгына беркетелә. Хезмәтләре физиол., сан., ш.у. гигиена, төньяк халыклары этнографиясе фәннәрен укытуны оештыруга карый. Казан губернасында земство сан. хезмәтен оештыручы.

Хезм.: О профилактических мерах против распространения сифилиса // Протоколы заседания Харьков. мед. об-ва. 1885. № 10; Оспа и оспопрививание. СПб., 1892.

*Әд.:* Щиголев И.И. Аркадий Иванович Якобий — гигиенист, этнограф. Клинцы, 2006.

**ЯКОБСО́Н** Абрам Львович (1.11.1923, Казан — 10.12.1997, шунда ук), сан. табибе, сәламәтлек саклау өлкәсе эшлеклесе, ТАССР-ның, РФнең атказ. табибе (1973, 1995). Ленинград стомат. ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), Татарстанда эшли: ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка сан.-эпид. станциясендә, 1965 елдан баш табиб (сәламәтлек саклау министры урынбасары, баш дәүләт сан. табибе). 1984 тән Респ-ка дәүләт сан.-эпид. күзәтчелеге хезмәтенең метрология һәм стандартлаштыру төркеме җитәкчесе. Респ-каның сәламәтлек саклау министры урынбасары буларак, Я. сан.-эпид. хезмәтенең сизелерлек күтәрелешен тәэмин итә: 1960–70 елларда респ-каның 24 районында сан.-эпид. станцияләре өчен бер типтагы биналар төзелә, санэпидстанцияләр югары квалификацияле сан. табибләре б-н тәэмин ителә. Шуның нәтиҗәсендә КамАЗ төзелеше киң колач алган чорда, илнең төрле почмакларыннан Чаллыга дистәләгән мең кеше агылып килгәндә, шәһәрнең үзендә һәм тирә-як районнарда эпидемияләр күзәтелми; респ-ка күләмендә ш.у. эпидемик куркынычсызлык саклана. Бөек Ватан сугышында



А.Е.Яковлев.

катнаша. Хезмәтләре авыруларны кисәтүгә юнәлдерелгән сан. күзәтчелегенә, йогышлы авыруларны булдырмый калуга карый. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Якобсон Абрам Львович // Казан. мед. журн. 1983. № 6.

**ЯКОБСО́Н** Леонид Вениаминович (15.1.1904, С.-Петербург — 17.10.1975, Мәскәү, Ленинградта җирләнә), балет артисты, балетмейстер, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957). 1926 елда Ленинград хореография уч-щесен (педагоглар В.Семёнов һәм В.Пономарёв) тәмамлаганнан соң, С.М.Киров исем. Ленинград опера һәм балет театрында эшли: 1926–33 тә артист, 1942–50 дә балет солисты һәм балетмейстер, 1956–75 тә балетмейстер. 1933–42 дә Зур театрда балет солисты һәм балетмейстер. 1969 да Ленинград «Хореография миниатюралары» труппасын оештыруга этәргеч бирә һәм аның б-н җитәкчелек итә. «Спартак» (А.Хачатурян), «Мәхәббәт новеллалары» («Новеллы любви», М.Равель музыкасы), «Тиль Уленшпигель» (Р.Штраус музыкасы), «Сольвейг» (Э.Григ музыкасы), «Унике» («Двенадцать», Б.Тищенко) балетларын; шактый хореографик миниатюралар, ш.и. «Туй кортежы» («Свадебный кортеж», М.Шагал картиналары буенча, Дм.Шостакович музыкасы, 1971), «Мәңгелек яз», «Үбү» («Вечная весна», «Поцелуй», О.Роден скульптуралары буенча, К.Дебюсси музыкасы), «XX гасыр экзерсисы» («Экзерсис XX века», И.С.Бах музыкасы) миниатюраларын куя. Я. иҗатында беренче татар «Шүрәле» (Ф.Яруллин) балетының куелышы аерым урын алып тора: 1940–41 дә Казанда премьераны әзерләү эше б-н җитәкчелек итә (Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле кичектерелә), 1950 дә С.М.Киров исем. Ленинград опера һәм балет театрында үз либреттосына куя (Сталин бүләге, 1951), аннары «Шүрәле» балеты Я. хореографиясендә Зур театрда (1955, 1960), Татар опера һәм балет театрында (1970, 1986, 2000) куела.

Ә с ә р.: Письма Новерру: Воспоминания и эссе. N.Y., 2001.

*Әд.:* Леонид Якобсон: Творческий путь балетмейстера, его балеты, миниатюры, исполнители. Л.-М., 1965; Д о б р о в о л ь с к а я Г.Н. Балетмейстер Леонид Якобсон. Л., 1968; У л а н о в а Г.С. Памяти Леонида Якобсона // Музыка и хореография современного балета. Л., 1977. Вып. 2; Я к о б с о н И., З а й д е л ь с о н В. Беседы о Леониде Якобсоне, или Необходимый разговор и письмо, посланное вслед. М., 1993.

*Ф.Ш.Салитова.*

**Я́КОВКА** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 10 *км* төньяктарак, Вятка елгасыннан 2 *км* читтә. 2010 елда 16 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1844 тә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да чиркәү-приход мәктәбе (1887 дә ачыла), вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 895,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 250, 1897 дә — 374, 1908 дә — 413, 1920 дә — 461, 1926 да — 460, 1949 да — 284, 1958 дә — 168, 1970 тә — 156, 1979 да — 116, 1989 да — 44, 2002 дә — 31 кеше.

**Я́КОВКИН** Авенир Александрович (21.5.1887, Уфа губ., Благовещенский з-ды — 18.11.1974, Киев), астроном, физика-матем. фән. д-ры (1938), Украина ССР ФА мөхбир әгъзасы (1951). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1910), шунда ук В.П.Энгельгардт исем. обсерваториядә эшли, проф. (1926 дан), директор (1927 дән). 1937 елдан Урал ун-тында (Свердловск ш.): астрономия каф. мөдире (1937–45), физика-матем. ф-ты деканы (1939–43). 1945–51 дә Киев ун-тында. 1951–67 дә Украина ССР ФАнең Баш астрономия обсерваториясендә (Киев), директор (1952–59). Хезмәтләре Айның фигурасы һәм әйләнешенә, теоретик астрономиягә һәм астрономик приборлар төзелеше мәсьәләләренә карый. Ай радиусының киңлектәге оптик либрациягә бәйлелеген (Яковкин эффекты) ачыклый. Айдагы бер кратерга Я. исеме бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вращение и фигура Луны // Изв. астрон. обсерватории им. В.П.Энгельгардта. 1939. № 21; 1945. № 23; Движение, вращение и фигура Луны // Луна. М., 1960; Формулы и эфемериды для полевых наблюдений на Луне. Киев, 1964 (автордаш).

*Әд.:* О с и п о в А.К. Авенир Александрович Яковкин (1887–1974) // Вестн. Киев. ун-та. Сер. Астрономия. 1976. № 18.

**Я́КОВКИН** Илья Фёдорович (12.7.1764, Казан губ., Пермь провинциясе Богородское а. — 26.3.1836, Казан), тарихчы, педагог, коллегия советнигы (1816). Руханилар нәселеннән. Вятка руханилар (1782), Петербург укытучылар (1786) семинарияләрен тәмамлый. 1782–83 елларда Вятка руханилар семинариясендә, 1787–98 дә патша сараендагы җырчылар корпусында, 1789–98 дә Пажлар корпусында (С.-Петербург) укыта. 1799–1804 тә Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе укытучысы һәм инспекторы, 1804–13 тә — директоры. Бер үк вакытта, 1805–19 да, Казан ун-тында: ординар проф. (1816 га кадәр), рус тарихы, географиясе һәм статистикасы каф. атказ. профессоры (1816 дан); 1806–13 тә студентлар инспекторы. Чынлыкта университетның җитәкчесе буларак, 1814 кә кадәр кайбер профессорларның, 1804 нең 5 ноябрендә кабул ителгән уставка нигезләнеп, бу уку йортында автономия принципларын кертергә тырышуларына кискен каршы чыга. Казан уку-укыту округы попечителе М.Л.Магницкий тарафыннан отставкага җибәрелә. 1819 дан Царское Селода (Петербург губ.), 1830 еллардан Казанда яши. «Немец, латин һәм рус телләренә тәрҗемәләр белән һәм грамматик үзенчәлекләре күрсәтелгән элгәреге рәвешле француз теле сүзлеге»н («Словарь французских речений первообразных, с немецким, латинским и российским переводами и с показанием грамматических принадлежностей», СПб., 1796) төзи. Царское Селоның тарихы һәм мәдәниятенә багышланган хезмәтләре: «Царское Село елъязмасы. Царское Село конторасы кәгазьләре буенча» («Царскосельский летописец. По бумагам царскосельской конторы», СПб., 1827), «Царское Село тарихы» («История села Царского», ч. 1–3, СПб., 1829–33), «Царское Селоны тасвирлау яки аны тамаша кылучыларга юл күрсәткеч» («Описание села Царского, или Спутник обозревающих оное», СПб., 1830). Гомуми тарих һәм Россия тарихы буенча дәреслекләр һәм уку-укыту ярдәмлекләре, ш.и. «Дөнья сурәте яки Бөтендөнья тормышы тасвирламасы» («Зрелище света, или Всемирное жизнеописание», СПб., 1789), «Иң мәшһүр Европа илләре тарихының вакыт исәбендә тасвирламасы» («Летосчислительное изображение истории знатнейших европейских государств» (СПб., 1794), «Борынгы гомуми тарихның вакыт исәбендә тасвирламасы» («Летосчислительное изображение древней всемирной истории», СПб., 1798), «Россия тарихының вакыт исәбендә тасвирламасы» («Летосчислительное изображение российской истории», СПб., 1798; 2 нче басмасы 1814), «Гомуми тарих дәреслеге» («Учебник всемирной истории», СПб., 1798), «Кыскача Россия тарихы дәреслеге» («Учебник краткой российской истории», СПб., 1799).

Х е з м.: История Роберта, герцога Норманского, прозванного Дьяволом. СПб., 1785; Замечания, наблюдения и мысли о снабжении г.Казани волжской или кабанной водой, о качестве их и способах сделать кабанные воды обильными и проточными // Заволжский муравей. 1833. № 17.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1.

**Я́КОВЛЕВ** Алексей Ефимович (24.9.1903, Казан губ., Лаеш өязе Иванаево а. — 8.6.1991, Мәскәү), гв. генерал-лейтенанты (1945). Керәшен татар. Казан үзәк татар-керәшен мәктәбен тәмамлый (1917). 1929–35 елларда Казандагы 6 нчы берләштерелгән татар-башкорт хәрби мәктәбендә башлык урынбасары. 1939 дан Одесса пехота уч-щесенең батальон командиры. Бөек Ватан сугышында дивизия командиры, штаб башлыгы һәм армия командующие. 1945–69 да Эстония хәрби корпусы командиры, М.В.Фрунзе исем. хәрби академиядә каф. һәм СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. академиясендә факультет башлыгы.

Ә с ә р.: Сквозь огонь: Записки генерала. К., 1985.

*М.З.Хәбибуллин.*

**Я́КОВЛЕВ** Борис Александрович (27.6.1932, Чабаксар ш. — 27.8.1992, Лениногорск ш.),

геолог-геофизик, геол.-минер. фән. д-ры (1988), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), «Татнефтегеофизика» ҖБдә эшли, геофизик партия башлыгы (1958–60). Бер үк вакытта, 1957 елдан, И.М.Губкин исем. Дәүләт нефть һәм газ академиясенең Татарстан кичке ф-тында укыта (Әлмәт ш., 1962–92 дә декан, 1989 дан проф.). Хезмәтләре җылылык физикасына, тирәндәге тектоника, Татарстан терр-ясендә углеводород чыганаклары геологиясенә карый. Я. тау токымнарының һәм катлам сыеклыкларының кайбер җылылык үзлекләрен, Идел-Урал өлкәсенең җир асты байлыкларының геотермик шартлары үзенчәлекләрен билгеләде, углеводородлар туплану өчен уңайлы зоналарны ачыклый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Определение и использование тепловых свойств горных пород и пластовых жидкостей нефтяных месторождений. М., 1969 (автордаш); Решение задач нефтяной геологии методами термометрии. М., 1979.

**Я́КОВЛЕВ** Валерий Анатольевич (2.8.1953, Әлки р-ны Чуаш Борнае а. — 14.8.2014, шунда ук), гидробиолог, биол. фән. д-ры (1999), проф. (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1980), РФАнең Кола гыйльми үзәгендә (Мурманск өлкәсенең Апатиты ш.) эшли. 1997–2002 елларда ТР ФАнең Табигать системалары экологиясе ин-тының гидробиол. лаб-ясе мөдире. 2002 дән Казан ун-тында, умырткалылар зоологиясе каф. мөдире (2009 дан). Хезмәтләре гидробиол., экология, паразитологиягә карый. Я. Мурманск өлкәсендә, Финляндия һәм Норвегиянең төньяк районнарында су да яшәүче умырткасызларның составын тикшерә; Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларында умырткасызларның ят төрләрен (кысласыманнар һәм Урта Идел өчен яңа, чыгышы Америкадан булган Physella acuta моллюскасы) ача. Аның тарафыннан төче сулы экосистемаларда антропоген йогынты шартларында барлыкка килгән тискәре экологик күренешләр күрсәтелә; төрле типтагы сулыкларда су сыйфатын бәяләүнең гидробиол. алымнары эшләнә.

Х е з м.: История зоологических исследований в Казанском университете: XIX-XX вв. К., 2003 (автордаш); Пресноводный зообентос северной Фенноскандии (разнообразие, структура и антропогенная динамика): В 2 ч. Апатиты, 2005; Охраняемые водные беспозвоночные организмы Республики Татарстан. К., 2010.

**Я́КОВЛЕВ** Валерий Иванович (4.5.1944, Уфа ш.), этнограф, музыка белгече, баянчы, дирижёр, тарих фән. д-ры (2002), проф. (2005), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2000). Казан. консерваториясен тәмамлаганнан соң (1969), шунда ук эшли, 2007 елдан башкару сәнгате теориясе һәм тарихы каф. мөдире. Хезмәтләре Урта Идел һәм Урал буе халыкларының музыка уен кораллары тарихына карый. Традицион татар муз. культурасын һәм музыка сәнгатен өйрәнүгә зур өлеш кертә. Этнографик экспедицияләрне, халык музыка уен кораллары күргәзмәләрен оештыручы һәм җитәкчесе. Баянчы һәм халык музыка уен кораллары оркестры дирижёры буларак концертлар куя.

Х е з м.: Традиционные музыкальные инструменты народов Среднего Поволжья. К., 1991; Музыкальные инструменты Национального музея Прокопьевич Бусыгин. К., 2003; Республики Татарстан: Каталог. К., 2007.

**Я́КОВЛЕВ** Владимир Алексеевич (10.1.1951, Ростов өлкәсенең Новошахтинск ш.), балет артисты, балетмейстер, ТАССРның һәм РФнең атказ. артисты (1980, 1996). РФ Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1982). 1969 елда Ленинград акад. хореография уч-щесен (педагог Н.Зубковский) тәмамлаганнан соң, Татар опера һәм балет театрында эшли: 1969–89 да балет солисты һәм баш балетмейстер (1988 дән), 1989 дан балет труппасының сәнгать җитәкчесе. Бер үк вакытта Казан музыка уч-щесендә укыта һәм хореография бүлеге б-н җитәкчелек итә (1988), Казан хореография уч-щесенең сәнгать җитәкчесе (1993–98). 2013 тә Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тын (хәзер Казан мәдәният ин-ты)



В.А. Я к о в л е в Пётр Леонтьевич ролендә («Анюта» балеты, В.Гаврилин). 1990.

тәмамлый. Талантлы биюче һәм актёр Я. Шамакай («Аккош күле», П.Чайковский), Нурали («Бакчасарай фонтаны», Б.Асафьев), Бенволио («Ромео һәм Джульетта», С.Прокофьев), Патша («Канатлы ат», Р.Щедрин), Аллаһ («Дөнья яралу», А.Петров), Журден («Дворяннар арасындагы мещан», Р.Штраус), Пётр Леонтьевич («Анюта», В.Гаврилин), Шүрәле (шул исем. әсәр буенча, Ф.Яруллин) һ.б. хореография партияләрен башкара. Татар опера һәм балет театрында Я. редакциясендә «Щелкунчик», «Йокыга талган гүзәл» («Спящая красавица», П.Чайковский, 1999, 2003), «Шүрәле» (Ф.Яруллин, 2000), «Коппелия» (Л.Делиб, 2007), «Анюта» (В.Гаврилин, 2011), «Дон Кихот» (Л.Минкус, 2015) балетлары куела. *Нуриев Р. исемендәге классик балет фестивален* оештыручыларның берсе. Медальләр б-н бүләкләнә.

*В.Н.Горшков.*

**Я́КОВЛЕВ** Геннадий Евгеньевич (17.2.1931, Новороссийск ш.), геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (1985), проф. (1986), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1954), шунда ук эшли, геол. эзләнүләрнең геофизик алымнары каф. мөдире (1979–97). Хезмәтләре углеводород чыганакларын эзләү һәм разведкалауның геофизик алымнарына карый. Геофизик разведкалау өчен гадәти электр кырлары куллану буенча фәнни юнәлешкә нигез салучыларның



Владимир А.Яковлев.



Е.Г.Яковлев.

берсе. Электр кулланылышлы кыр разведкасы эшләре күләмен санга күчереп исәпләү ысулын, нефть-газ катламнарын геофизик ысуллар б-н билгеләү методикасын, бертөрле диярлек кырдагы скважиналар электрометриясе алымын эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Электрометрия скважин в квазиоднородном поле. К., 1984; Исследование скважин большими градиент-зондами. М., 1990.

**Я́КОВЛЕВ** Евстафий Григорьевич (27.4.1914, Самара губ., Бөгелмә өязе, хәзер Лениногорск р-ны Сходнево-Чертанла а. – 16.4.1945, Германия терр-ясендә җирләнә), Сов. Союзы Герое (31.5.1945, үлгәннән соң), өлкән лейтенант. Кече лейтенантлар курсларын тәмамлый (1943). Туган авылында тракторчы булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1054 нче укчы полкның (5 нче удар армиянең 301 нче укчы дивизиясе, Белоруссия фронты) рота командиры. Я. Кавказдан Германиягә кадәр сугыш юлы үтә. 1945 нең 16 апрелендә Вербиг (хәзер Нойлангзов, Зелов шәһәренең төньяк-көнчыгышы, Германия) тимер юл станциясе янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: Я. җитәкчелегендәге рота дошманның оборонасын өзә, совет танкларының хәрәкәтенә комачаулаган фаустчы төркемен юк итә; сугышта һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Туган авылында Я.ка обелиск куелган, Лениногорск шәһәренең бер урамына Я. исеме бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**Я́КОВЛЕВ** Иван Яковлевич (25.4.1848, Сембер губ., Буа өязе Кошки-Яңа Тимбай а. — 23.10.1930, Мәскәү), педагог-мәгърифәтче, чуаш мәдәнияте эшлеклесе, Н.И.Ильминскийның укучысы. Чыгышы б-н крәстияннәрдән. Иртә ятим кала, авылдашы гаиләсендә тәрбияләнә. Борындык удел уч-щесен (1860) һәм Сембер ир балалар гимназиясе каршындагы җир үлчәүче-таксаторлар сыйныфларын (1863) тәмамлый. Сызрань шәһәрендә җир үлчәүче булып эшли; 1867–70 елларда Сембер ир балалар гимназиясендә, аннары Казан ун-тында укый (1875 тә тәмамлый). 1868 дә үз акчасына һәм хәйрия акчасына чуаш балаларын уку йортларына керергә әзерләү өчен мәктәп оештыра. Сембер губернасы халык уч-щеләре инспекторы И.Н.Ульянов ярдәме б-н 1871 дә мәктәп дәүләт бюджетыннан



И.Я.Яковлев.

финанслана башлый, 1877 дә Сембер Үзәк чуаш мәктәбе итеп үзгәртелә (1878 дә мәктәп каршында кыз балалар бүлеге ачыла). 1890 да аның җирлегендә Сембер чуаш укытучылар мәктәбе булдырыла, ул милли мәдәниятне үстерү үзәгенә әверелә. Университетның 1 нче курсында укыганда Н.И.Ильминский җитәкчелегендә һәм профессорлар Г.С.Саблуков һәм И.Н.Булич ярдәме б-н Я. чуаш алфавитын булдыру өстендә эшли башлый. Аның нигезендә 1873 тә «Чуашлар өчен рус алфавиты белән берләштерелгән әлифба» («Букварь для чуваш с присоединением русской азбуки») бастырыла.

1883–1903 тә Я. Казан уку-укыту округының чуаш мәктәпләре инспекторы, бер үк вакытта, Сембер чуаш мәктәбе җитәкчесе (1919 ның октябренә кадәр), Урта Идел буенда яңа чуаш, татар һәм башка милли мәктәпләр ачылуына ярдәм итә. Уку-укыту округында чуаш мәктәпләренең саны 1875 тә 8 дән 1903 тә 45 кә кадәр арта. Чуашлар өчен мәктәптә белем бирүнең прогрессив системасын, чуаш мәктәпләре өчен укыту методикасын эшли. Мәктәпләрдә уку өчен халык авыз иҗаты үрнәкләрен файдаланып төзелгән китаплар авторы. Л.Н.Толстойның «Уку китаплары»ның («Книги для чтения») дүртесен дә, А.С.Пушкин, И.А.Крылов, Н.А.Некрасовның аерым әсәрләрен чуаш теленә тәрҗемә итә. 1909 да шагыйрь К.В.Иванов б-н бергә «Чуаш телендәге әлифбадан соң беренче уку китабы»н («Первая книга для чтения после букваря на чувашском языке») бастыра. Чуаш телен, үз халкының мәдәни үзенчәлеклелеген яклап, Я. миссионер Н.И.Ильминскийның идеяләрен хуплый (к. *Ильминский системасы*), чуашларны христианлаштыру, аларны рус халкы һәм аның мәдәнияте б-н якынайту сәясәтен уздыра. Шул сәбәпле чуаш милләтчеләре лидерлары аны халыкны руслаштыруда, ә рус шовинистлары сепаратизмда гаепләләр. Я. өстеннән килгән шикаятьләрне тикшерүдә 1914 тә Россия мәгариф министры П.А.Кассо үзе, 1918 дә В.И.Ленин катнаша.

1922 нең октябрендә Я. Мәскәүгә күченә. 1927 дә Чуаш мәдәнияте җәмгыятенең мактаулы әгъзасы итеп сайлана. 1928 нең 14 октябрендә ил җәмәгатьчелеге Сембер чуаш мәктәбенең 60 еллыгын һәм аны нигезләүче Я.ның 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Бу даталарга багышланган тантаналы җыелышта РСФСР мәгариф халык комиссары А.В.Луначарский катнаша, ул билгеләгәнчә, Я. «мәгърифәтче генә түгел, бәлки үз милләтенең мәдәни юлбашчысы да». Я. исеме Чуаш пед. ин-тына бирелә (1958), Чабаксар шәһәрендә аңа һәйкәл куела, Кошки-Яңа Тимбай авылында мемориаль музей ачыла.

Х е з м.: Сказки и предания чуваш. Симбирск, 1908; Духовное завещание чувашскому народу. Чебоксары, 1992; Моя жизнь: Воспоминания. М., 1997.

*Әд.:* Итоги юбилейной научной сессии, посвящённой столетию со дня рождения И.Я.Яковлева // Зап. Чуваш. науч.-исслед. ин-та языка, литературы и истории. Чебоксары, 1949; Я к о в л е в А.И. Иван Яковлевич Яковлев (1848–1930). Чебоксары, 1958; И.Я.Яковлев и его школа // Уч. зап. Чуваш. гос. пед. ин-та. Чебоксары, 1971. Вып. 33; К р а с н о в Н.Г. Иван Яковлевич Яковлев: Жизнь. Деятельность. Педагогические идеи: Очерки. Чебоксары, 1976; ш у л у к. Выдающийся чувашский педагог-просветитель. Чебоксары, 1992; Очерки истории культуры дореволюционной Чувашии. Чебоксары, 1985; Чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2011. Т. 4.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**Я́КОВЛЕВ И.Я. МУЗЕ́Е**, Тәтеш районының Кошки-Яңа Тимбай авылында. Мәктәп музее буларак 1985 елда оештырыла, 1998 дә ТР МКның 1992 ел 20 март карары нигезендә муниципаль музей буларак ачыла. Музейны оештыруда укытучылар В.Л.Ефремов, С.Н.Лазарев, А.С.Байдеряков катнашалар. Экспозициянең фәнни концепциясе авторы — Чуаш Респ-касы милли музее хезмәткәре В.Г.Шляхина, сәнгать проекты авторы — Чуаш Респ-касының атказ. рәссамы Ю.П.Матросов. Экспозицияне булдыруда Чуаш Респ-касы Милли музее хезмәткәрләре А.М.Лаптева, Т.Н.Орлова, ТР Милли музее хезмәткәрләре С.И.Матвеев (иҗади-сәнгать төркеме җитәкчесе), А.Д.Хәйруллина, Л.Е.Еникеева, Т.Б.Чканова; Чуаш Респ-касы рәссамнары Ю.Ю.Ювенальев, Ю.М.Смирнов өлеш кертәләр. Музей бер катлы агач бинада урнашкан (И.Я.Яковлев акчасына төзелгән элекке уч-ще бинасы, 1895). Экспозиция мәйданы — 220 $м^2$, фондларында 1161 саклау берәмлеге исәпләнә, 4 бүлектән тора: «Кошки-Яңа Тимбай училищесе тарихы», «Авыл тарихы», «И.Я.Яковлевның тормышы һәм эшчәнлеге», «Бөек Ватан сугышы». Экспонатлар арасында — И.Я.Яковлевның кара савыты, көнкүреш предметлары, чуашларның халык гамәли-бизәлеш сәнгате эшләнмәләре, Кошки-Яңа Тимбай чиркәве рухание чапаны ризасы (20 йөз башы). Музей ел саен ачылу көнен (11 апрель), Җиңү көнен (9 май) билгеләп уза. Директоры — А.А.Пыркин (1998 дән).





И.Я.Яковлев музее. 1. Музей бинасы; 2. Экспозиция фрагменты.

**Я́КОВЛЕВ** Юрий Петрович (6.1.1926, Казан), авиация моторлары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1972), проф. (1973). 1949 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, фәнни-тикшерену секторы башлыгы (1962–71), проректор (1971–75). 1975–90 да СССР Югары һәм урта махсус белем бирү министрлыгы (Мәскәү) бүлеге мөдире. Хезмәтләре авиация һәм ракета моторларын суыту системаларындагы җылылык алмашуга карый. Я. җылылык энергиясе объектларында кайнау күренешенең критик режимнарын тикшерә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Интенсификация теплообмена в сверхкритических диатермических теплообменниках // Изв. вузов. Энергетика. 1967. № 12; Особенности расчёта лучистого теплообмена в системах диатермических тел, разделённых поглощающей и рассеивающей средой // Изв. вузов. Авиац. техника. 1972. № 3.

**Я́КОВЛЕВО** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 35 *км* көнбатыштарак, Әнҗерә елгасы буенда. 2010 елда 390 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 88%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 нән Яковлев Пүчинкәсе исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да 4 тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3302 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Казиле волостенда. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 1247, 1887 дә — 1426, 1905 тә — 975, 1920 дә — 1326, 1926 да — 1537, 1938 дә — 1119, 1949 да — 647, 1958 дә — 420, 1970 тә — 387, 1979 да — 377, 1989 да — 422, 2002 дә — 383 кеше.

**ЯКТЫ́ АЛА́Н** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 51 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мордвасу елгасы бассейнында. 2010 елда 22 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1920 дә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Зөя кантоны Тәмте волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Кама Тамагы, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1926 да — 24, 1938 дә — 225, 1949 да — 127, 1958 дә — 225, 1970 тә — 196, 1979 да — 127, 1989 да — 54, 2002 дә — 32 кеше.

**ЯКТЫ́ ЕЛГА́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 7 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 2 кеше (татарлар) яши. 1930 да нигез салына. Оешкан көненнән Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 111, 1949 да — 103, 1958 дә — 101, 1970 тә — 95, 1979 да — 67, 1989 да — 2, 2002 дә — 1 кеше.

**ЯКТЫ́ ЙОЛДЫ́З** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 55 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мордвасу елгасы бассейнында. 1930 да нигез салына. Оешкан көненнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 112, 1949 да — 124, 1958 дә — 91, 1970 тә — 53, 1979 да — 35, 1989 да — 20, 2002 дә — даими яшәүчеләр юк.

**ЯКТЫ́ КӨН** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 8 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 80 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ит терлеге асрау. Башлангыч мәктәп. 1932 дә нигез салына. Оешкан көненнән Арча р-нында. Халык саны: 1938 дә — 184, 1949 да — 178, 1958 дә — 148, 1970 тә — 138, 1979 да — 121, 1989 да — 78, 2002 дә — 109 кеше.

**ЯКТЫ́ КҮЛ**, Көнбатыш Кама алдында. Сумка елгасы бассейнының уңъяк яр өлешендә, Яшел Үзән р-ны Яктыкүл авылы янында урнашкан. Су өслегенең мәйданы 3,45 *га*. Суының күләме якынча 120 мең $м^3$. Озынлыгы 295 *м*, иң зур киңлеге 172 *м*. Уртача тирәнлеге 3,4 *м*, иң зур тирәнлеге 9,5 *м*. Күл



Якты күл. Яшел Үзән районы.

карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча, озынча түгәрәк. Ярларының кайбер урыннары таллар б-н капланган, көнчыгыш яктагы яры текәрәк һәм күтәренке. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, йомшак, җиңелчә минеральләшкән, тоссез. Үтә күренмәлелеге 57 *см*. Ял итү максатларында файдаланыла.

**ЯКТЫ́ ТА́У** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән р-ныннан 30 *км* төньяк-көнбатыштарак Сөлчә елгасы (Олы Сөлчә елгасының уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 141 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, китапханә. Мәчет. 1929 да нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Котыш волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1949 да — 412, 1958 дә — 461, 1970 тә — 547, 1979 да — 471, 1989 да — 261, 2002 дә — 170 кеше.

**ЯКТЫ́ ЮЛ** посёлогы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Куэтле Елга елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 30 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — ит терлеге асрау. 1920 дә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Әлки волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 164, 1949 да — 115, 1958 дә — 98, 1970 тә — 113, 1979 да — 101, 1989 да — 61, 2002 дә — 37 кеше.

**«ЯКТЫ́ ЮЛ»**, сәяси, фәнни, әдәби, пед. журнал. Вятка губернасы мәгариф бүлеге органы. 1920 елның февраленнән 1921 нең ахырына кадәр Малмыж шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 16 саны чыга. Мөхәррире — Г.Ишмөхәммәтов. Актив авторлары арасында — С.Әхмәров, Н.Бәхтияров, Ю.Баязитов, Ф.Гасыймов, Г.Динмөхәммәтов, Г.Ишмөхәммәтов, Д.Сәгыйтова, С.Фәйзуллин, Ф.Хамматов һ.б. Журналда үзәк һәм җирле хакимият органнарының мәгариф һәм тәрбия мәсьәләләре турындагы декретлары, карарлары басыла. Мәктәпкәчә һәм мәктәптә белем бирү, уку йортларын методик кулланмалар б-н тәэмин итү, уку-укыту һәм тәрбия эшен камилләштерү мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. Г.Сәгъди, И.Сәүбән, Г.Хәбиб, Ф.Хәмиди һ.б.ның әдәби әсәрләре һәм әдәби-тәнкыйть язмалары дөнья күрә.

**ЯКТЫ́ ЯЛА́Н** (Яшәр) авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөгелмә — Азнакай автомобиль юлы буенда. 2010 елда 60 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1920 дә нигез салына. Беренче исеме — Алга, 1930 еллардан хәзерге исемен йөртә. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостенда. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1926 да — 88, 1938 дә — 175, 1949 да — 141, 1958 дә — 119, 1970 тә — 126, 1979 да — 93, 1989 да — 58, 2002 дә — 74 кеше.

**ЯКТЫКҮ́Л** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 23 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 87 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ит терлеге асрау. Башлангыч мәктәп. 1920 дә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Тымытык волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 187, 1949 да — 207, 1958 дә — 180, 1970 тә — 198, 1979 да — 130, 1989 да — 111, 2002 дә — 107 кеше.

**ЯКТЫКҮ́Л** посёлогы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Солонка елгасы бассейнында. 2010 елда 1 кеше (чуаш) яши. 1930 да нигез салына. Оешкан көненнән Казан авыл районында. 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 56, 1958 дә — 45, 1970 тә — 30, 2002 дә — 1 кеше.

**ЯКТЫКҮ́Л** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 12 *км* көньяктарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2010 елда 731 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 75%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, чүлмәк һәм тәгәрмәч, арба, чана ясау, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Я.дә земство почта станциясе, миссионерлык мәктәбе (1880 дә ачыла) була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2135 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 575, 1897 дә — 1164, 1913 тә — 1410, 1920 дә — 1303, 1926 да — 1345, 1938 дә — 1133, 1949 да — 835, 1958 дә — 884, 1970 тә — 910, 1979 да — 749, 1989 да — 634, 2002 дә — 700 кеше.

**ЯКТЫКҮ́Л** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кондырча елгасы буенда. 2010 елда 394 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Егоркино волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән Нурлат) р-нында. Халык саны: 1926 да — 33, 1938 дә — 355, 1949 да — 451, 1958 дә — 404, 1970 тә — 493, 1979 да — 454, 1989 да — 391, 2002 дә — 391 кеше.

**ЯКТЫКҮ́Л** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 29 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сумка елгасы буенда. 2010 елда 4 кеше (руслар) яши. 1919 елларда нигез салына. Светлозёрка исеме б-н билгеле. Оешкан көненнән Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында, 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1920 дә — 61, 1926 да — 62, 1938 дә — 65, 1949 да — 150, 1958 дә — 68, 1970 тә — 19, 1979 да — 10, 1989 да — 11, 2002 дә — 3 кеше.

**ЯКУ́БОВ** Камил Лотферахман улы (21.3.1894, Самара губ., Бөгелмә өязе Әптекәй а. — 25.6.1919, Казан), сәясәт эшлеклесе. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, Казан укытучылар мәктәбен тәмамлый (1914). 1915–17 елларда Көнбатыш фронтның 2 нче армиясе мөселман солдатлары арасында революцион эш алып бара. Казанда совет хакимиятен урнаштыруда актив катнаша, Вакытлы революцион ком-т әгъзасы. 1918 дә Казан советының Мөселман комис-тын оештыручыларның берсе, Шәһәрне саклау революцион штабы әгъзасы. 1918–19 да Шәрекъ халыкларының коммунистик оешмалары үзәк бюросы әгъзасы, Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге башлыгы. Адмирал А.В.Колчакның ак армиясенә каршы көрәштә актив катнаша. Берничә тапкыр Көнчыгыш фронт частьларына барып кайта. Кызыл Армиянең мөселман берләшмәләрен төзүдә катнаша. Татар запас батальоны сугышчылары алдында чыгыш ясаганда үтерелә.

*Әд.:* М ө х ә р р ә м о в М., Г ы й з з ә т у л л и н И. Халык бәхете хакына // Казан утлары. 1984. № 3; М у х а р я м о в М. Камил Якубов. К., 1964; Г и з а т у л л и н И. Жизнь, отданная борьбе // Советская Татария. 1984. 20 марта.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ЯКУ́БОВ** Нәҗип Садыйк улы (5.4.1922, Казан — 4.2.2003, шунда ук), инженер-икътисадчы, Казан язу җайланмалары з-ды директоры (1962–87), РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1981). Казан авиация техникумын (1942), Бөтенсоюз читтән торып уку политехник ин-тын (Мәскәү, 1953) тәмамлый. 1941–45 елларда Казанның 22 нче авиация з-дында конструктор булып эшли. 1945–48 дә СССР Авиация сәнәгате министрлыгының 4 нче базис склады башлыгы (Казан). 1948–60 та 230 нчы з-дта катнаш җитештерү бюросы башлыгы, цех, лаб. башлыгы урынбасары, баш технолог урынбасары (Казан). 1960 тан Казан язу җайланмалары з-дында баш инженер. Я. җитәкчелегендә пр-тиедә техник реконструкция уздырыла, исәпләү техникасының күп кенә яңа үрнәкләрен эшләп чыгару үзләштерелә, социаль-көнкүреш объектлары төзелә. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Ленин ордены, Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының өч көмеш медале б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ЯКУ́БОВ** Семён Семёнович (17.7.1947, Курган ш.), спортчы, тренер (автомобиль спорты), ТРның, РФнең атказ. спорт остасы (2000, 2003), ТРның, РФнең атказ. тренеры (2000, 2002); хакимият хезмәткәре, ТРның атказ. машина төзүчесе (2001). Курган машиналар төзү ин-тын тәмамлый (1970). Йөк автомобильләре арасында ралли-марафоннарда җиңүче: Россия чемпионаты 1997, «Мастер-ралли» 1996 (Париж–Мәскәү–Улан-Батор), «Дезерт–Челлендж» 1999–2002 (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре), «Дакар» 2000, 2002–04, 2006, «Бажа–Италия» 2000, «Оптик-2000» 2000 (Тунис). «Оптик-2000» 1997 (Тунис), «Гранада–Дакар» 1999, «Дезерт–Челлендж» 2000, «Париж–Дакар» 2000 раллиларында көмеш медаль ала. Юлсыз урындагы ралли буенча Дөнья кубогы иясе 1996, 2000. 1970 елдан «КАМАЗ» АҖдә: Фәнни-техник үзәк директоры (1987–95), АҖ президенты (1995– 2000), ген. директоры (2000 нән) киңәшчесе. Бер үк вакытта, 1988–2012 дә, «КАМАЗ-Мастер» спорт командасы (Чаллы ш.) җитәкчесе, тренеры, штурманы. Шәкертләре арасында — Россиянең атказ. спорт осталары Н.М.*Баһаветдинов*, Ф.Т.*Бәдретдинов*, Ф.З.*Кәбиров*, С.Г.*Савостин*, В.Г.*Чагин*. РФ Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Батырлык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы (2001).

**ЯКУ́БОВА** Ольга Ивановна (28.12.1953, Омск өлкәсе, Исилкүл ш.), рәссам-дизайнер, РФнең атказ. рәссамы (2013). 1976 елда Свердловск архит-ра ин-тын тәмамлый. 1976 дан Чаллы шәһәрендә КамАЗ Баш архитекторы бүлегендә эшли. 1982–85 тә Татарстан Рәссамнар берлеге каршындагы Чаллы сәнгать комб-тында проектлау эшләре б-н шөгыльләнә. Я.ның проектлары буенча балалар шәһәрчекләре, фонтаннар һәм скульптуралар, М.Җәлил скверы төзелә, балалар бакчалары, мәктәпләр, рестораннар, «Трансагентство» интерьерлары бизәлә. 1985 тән заводның экспорт хезмәте реклама бүлеген (соңыннан КАМАЗның реклама агентлыгы итеп үзгәртелә) җитәкли. 2000 нән — «КАМАЗ-Мастер» командасының пиар-директоры. «КАМАЗ-Мастер» командасының дизайн-стиль авторы (Россия Сәнгать академиясенең Алтын медале б-н бүләкләнә), Автоспорт үзәге (җитештерү цехы, спорт-сәламәтләндерү блогы, «Мираж» концерт залы) аның проектлары буенча бизәлә. РФ Дәүләт бүләге (2000), Россия хатын-кызларының Җәмәгатьчелек тарафыннан танылу «Олимпия» премиясе лауреаты, Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы.

**ЯКУБО́ВСКИЙ** Александр Юрьевич (20.1.1886, С.-Петербург — 21.3.1953, Ленинград), тарихчы, шәркыятьче галим, археолог, тарих фән. д-ры (1935), СССР ФА мөхбир әгъзасы (1943), Таҗикстан ССР ФА академигы (1951). Петербург ун-тының тарих-филол. ф-тын (1913), Ленинград ун-тының шәркыять ф-тын (1924) тәмамлый. 1925 елдан Матди мәдәният тарихы дәүләт академиясендә (1937 дән — СССР ФАнең Матди мәдәният тарихы ин-ты) эшли. Бер үк вакытта, 1928 дән, Эрмитаж хезмәткәре, 1935 тән Ленинград ун-ты профессоры. 1945 тән Согыд-Таҗик археол. экспедициясе җитәкчесе. Хезмәтләре Алгы һәм Урта Азия, Кавказ халыкларының урта гасырлар тарихына, мәдәнияте, килеп чыгышы, сыйнфый көрәше мәсьәләләренә карый. Я.ның «Сарай Бәркәдә һөнәр сәнәгате килеп чыгышы мәсьәләсенә карата» («К вопросу о происхождении ремесленной промышленности Сарая Берке», Л., 1931), «Алтын Урданың җимерелүе тарихыннан» («Из истории падения Золотой Орды», М., 1947), «IX һәм X йөзләрдә Итил һәм Болгарның тарихи топографиясе мәсьәләсенә карата» («К вопросу об исторической топографии Итиля и Болгар в IX и X веках», М., 1948), «Сарай Бәркә — Алтын Урда башкаласы» («Сарай Берке — столица Золотой Орды», Л., 1953) хезмәтләре Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда тарихының төрле аспектларына багышлана. Б.Д.Греков б-н бергә «Алтын Урда: Җучи олысының XIII–XIV йөзләрдә оешу һәм чәчәк ату чорындагы тарихы турында очерк» («Золотая Орда: Очерк истории Улуса Джучи в период сложения и расцвета в XIII–XIV вв.», Л., 1937; 2 нче басмасы «Алтын Урда һәм аның таркалуы» («Золотая Орда и её падение», М.–Л., 1950) монографиясен яза. Бу хезмәт Алтын Урда дәүләте тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә, аның Русь б-н мөнәсәбәтләрен ача. Я. татар халкының болгар чыгышлы булуы теориясен яклый. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1952). Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Самарканд при Тимуре и тимуридах. Л., 1933; Культура и искусство Востока в памятниках Эрмитажа. Л., 1937; К вопросу об этногенезе узбекского народа. Таш., 1941.

*Әд.:* Б е л е н и ц к и й А.М., Д ь я к о н о в М.М. Памяти А.Ю.Якубовского // Краткие сообщ. Ин-та истории материальной культуры. М., 1953. Вып. 51; Памяти А.Ю.Якубовского // Советская археология. 1954. Т. 19; Л у н и н Б.В. Биобиблиографические очерки о деятелях общественных наук в Узбекистане. Таш., 1977. Т. 2.

**ЯКУБО́ВСКИЙ** Александр Якуб Адамович (20.4.1932, Белоруссия ССР, Витебск өлкәсенең Поставы р-ны Комаи а. – 14.9.1998, Белоруссия Респ-касы, Минск, Смиловичида җирләнә), лингвист, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, журналист, энциклопедист, 12 томлык «Белоруссия Совет Энциклопедиясе»н («Белорусская Советская Энциклопедия», 1968–76) һәм 5 томлык «Белоруссия табигате энциклопедиясе»н («Энцыклапедыя прыроды Беларусі», 1983–86) әзерләп чыгаруны оештыручыларның берсе, Белоруссия ССРның Дәүләт бүләге лауреаты (1976). Минск укытучылар ин-тының тарих ф-тын (1955), Минск ун-тының география ф-тын (1962), белорус теле һәм әдәбияты бүлеген (1989) тәмамлый. Минск шәһәре мәктәпләрендә укытучы булып эшли, 1968 елдан «Белоруссия Совет Энциклопедиясе» Баш редакциясенең геогр., геол. һәм геофизика буенча тармак редакциясе мөдире.

1980 еллар ахырыннан Минск, Минск өлкәсе һәм Белоруссиядәге татар җәмгыятьләрендә мәдәни һәм дини тормыш мәсьәләләренә, Мәскәү һәм Казандагы татар иҗтимагый-мәдәни оешмалары, Кырым, Литва һәм Польша татарлары җәмгыятьләре б-н элемтәләр булдыруга зур игътибар бирә. Белоруссия татар-мөселманнарының 1990 да оешкан «Әл-Китаб» җәмгыятен нигезләүдә актив катнашучыларның берсе һәм вице-президенты. 1991 нең апрелендә аның башлангычында кварталга бер тапкыр «Байрам. Татары на зямлі Беларусі» ж-лы нәшер ителә башлый, 1998 гә кадәр баш мөхәррире була (1998–2002 дә баш мөхәррир – Белоруссия пед. ин-ты доценты И.Канапацкий).

1990 еллар башында Я. «Белоруссия, Литва һәм Польша татарлары» («Татары Беларусі, Літвы і Польшчы») энциклопедик басмасын әзерли башлый, лөгатьлеген төзи, соңрак «Белоруссия татарлары энциклопедиясе» концепциясенә күчеп, әзер мәкаләләрнең бер өлешен «Байрам» ж-лында бастыра; белорус телендәге төрки алынмалар лөгатьлеген төзергә керешә. Татар энциклопедиясен әзерләүнең башлангыч чорында Татар энциклопедиясе ин-ты хезмәткәрләренә фәнни-методик ярдәм күрсәтә, тәҗрибә уртаклаша, методик материаллар тапшыра.

Белорус һәм татар милли-мәдәни яңарышына керткән өлеше өчен «Рупліуцы тваe, Беларусь» («Синең эшлекләләрең, Беларусь») Мактау китабына кертелә (1998).

*Әд.:* Белорускaя Савецкая энцыклапедыя. Т.11. Минск, 1974; Думка прафесара Леаніда Лыча пра квартальнік беларускіх татар // Байрам. 1994. №2.
*Г.С.Сабирҗанов.*

**ЯКУ́БЧИК** Борис Иосифович (19.2.1928, Киев — 24.7.1979, Харьков ш.), спортчы, тренер (акробатика), СССРның мактаулы спорт остасы, РСФСРның атказ. тренеры (1965), пед. фән. канд. (1965). Киев физик культура ин-тын тәмамлый (1949). 1949 елдан Мед. ин-тында эшли (Винница ш.), 1952 дән Казан пед. ин-тында, гимнастика һәм йөзү каф. мөдире (1967). 1968 дән Пед. ин-тының физик тәрбия каф. мөдире (Винница ш.). Шәкертләре арасында 25 тән артык СССРның спорт остасы, РСФСР, «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятенең үзәк советы, СССР чемпионнары Ю.Дулатов, Е.Ермакова, А.Коломина, Р.Матросова, Г.Мансуров, В.Стенин.

**ЯКУ́ПОВ** Илгизәр Габделкаюм улы (17.2.1953, Казан), төзүче инженер, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2000), ТРның, РФнең атказ. төзүчесе (1997, 2004). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1981). 1969–77 елларда Казанның сәнәгать пр-тиеләрендә эшли. 1977 дән «Татстрой» АҖдә: балта остасы, мастер, 7 нче төзелеш-монтаж идарәсендә башлык урынбасары, башлык (1985 тән), баш инженер (1995 тән), Казан йортлар төзү комб-ты директоры (1996–99, 2006 дан), АҖ ген. директоры (1999–2006). Дәүләт бүләге торак, җәмәгать, сәнәгать биналары һәм корылмаларының күтәрүче-терәк системаларын булдыру һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. 2000–08 дә ТР халык депутаты. Медаль, ТРның Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

**ЯКУ́ПОВ** Илдус Дәүләт улы (9.10.1935, Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Иске Атлаш а.), композитор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993). 1964 елда Казан консерваториясен (А.Леманда композиция классы) тәмамлый. Я. иҗатына жанрлар күплеге, тематик төрлелек хас. Күпчелек әсәрләре балаларга (һәм башкаручы, һәм тыңлаучы сыйфатында) багышлана. Нечкә лиризм, көйнең милли нигезе, гармонияле тел байлыгы, композиторларга хас классик һәм заманча чаралардан иркен файдалануы аның иҗатының үзенчәлеген билгели. Я. әсәрләре арасында 12 симфония, инструменталь концертлар (оркестр б-н фортепиано, скрипка, виолончель, флейта өчен); «Акыллылык бәласе» («Горе от ума», А.Грибоедовның шул исем. пьесасы буенча, 1975), «Джельсомино ялганчылар илендә» («Джельсомино в стране лжецов», Дж.Родариның шул исем. әкияте буенча, 1976; Татар опера һәм балет театрында куела, 1991) опералары; «Италия турында әкиятләр» («Сказки об Италии», М.Горький әсәрләре буенча, 1965), «Хуҗа Насретдин» (Л.Соловьёв повесте буенча, 1966), «Вий» (Н.Гоголь повесте буенча, 1972), «Аккургаш солдат һәм балерина» («Оловянный солдатик и балерина», Г.Х.Андерсен әкияте буенча, 1976), «Атлантида һәлакәте» («Гибель Атлантиды», А.Беляев повесте буенча, 1977) балетлары һ.б. бар. Фортепиано өчен 24 прелюдия (1978), орган өчен 24 прелюдия һәм фуга (1981) цикллары алга таба Татарстан композиторлары иҗатында Көнбатыш Европа муз. классикасы традицияләре үсешенә булышлык итә. Я. — камера-инструменталь әсәрләр (фортепиано өчен квартетлар, сонаталар, сюиталар һәм пьесалар), Я.Райнис (тавыш, скрипка һәм фортепиано өчен, 1967), А.Пушкин (баритон һәм фортепиано өчен, 1977) шигырьләренә вокаль цикллар авторы. Аның тарафыннан 50 дән артык (ш.и үз текстларына) җыр языла. «Кыз җыры» (М.Җәлил шигыре), «Язгы таң» (Н.Гайсин шигыре), «Җир йолдызлары» (С.Шакир шигыре) һ.б. җырлар зур популярлык казана. «Бишек җыры» (1966), «Балалар өчен ун җыр» («Десять детских песен», 1968), «Батыр куян» (1977) җыентыкларына шактый гына балалар җырлары кергән. ТР Композиторлар берлеге әгъзасы.

*Әд.:* Композиторы Татарстана. М., 2009.

**ЯКУ́ПОВ** Мөнир Әхәт улы (25.3.1949, Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Иске Атлаш а.), җырчы (лирик-драматик баритон), педагог, ТРның халык артисты (1997). 1978 елда Казан консерваториясен (В.Воронов һәм М.Кольцов классы) тәмамлый. 1978 дән Татар опера һәм балет солисты. Төп опера партияләре: Эскамильо («Кармен», Ж.Бизе), Скарпиа («Тоска», Дж.Пуччини), Кенәз Игорь (шул исем. әсәр буенча, А.Бородин), Томский («Пики дамасы», П.Чайковский), Грязной («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Хан («Алтынчәч», Н.Җиһанов), Кәрим бай («Башмагым», Җ.Фәйзи), Фатыйх («Шагыйрь мәхәббәте», Р.Ахиярова). Я. репертуарында ш.у. классик һәм заманча оперетталардан, татар композиторларының муз. комедияләреннән дә рольләр бар: Фальк («Ярканат», И.Штраус), Шымчы («Башмагым», Җ. Фәйзи) һ.б. Театр труппасы б-н дә, солист буларак та Россиядә һәм чит илләрдә (Голландия, Дания, Бельгия, Англия, Португалия, Франция, АКШ, Төркия һ.б.) гастрольләрдә була. Я. — Ә.Бакировның «Тукай» операсында — Тукай һәм Б.Мөлековның «Сөембикә» операсында (концерт рәвешендә) Сафагәрәй партияләрен беренче башкаручы. 2011 дә Казан Кремлендә 1 нче Халыкара «Казан көзе» опера фестивале чикләрендә «Алтынчәч» (Н.Җиһанов) операсының яңа постановкасында Хан ролен башкара. Җырчының концерт репертуарын чит ил (ш.и. К.Дебюсси романслары циклы), рус, татар композиторлары (Р.Яхин, Р.Еникиев, Р.Белялов, М.Мозаффаров, Н.Җиһанов һ.б.) әсәрләре тәшкил итә. 2005 тән Казан консерваториясендә укыта.
*Ф.Ш.Салитова.*



М.Ә.Якупов.



Н.М. Якупов.

**ЯКУ́ПОВ** Назыйм Мөхәммәтҗан улы (7.7.1928, БАССРның Кушнаренко р-ны Карача-Елга а. — 20.2.2009, Одесса, Украина), тарихчы, тарих фән. д-ры (1970), проф. (1970), Сов. Союзы Герое (1956), Украина ССРның атказ. фән эшлеклесе (1987). Львов хәрби-сәяси уч-щесен (1951), Одесса ун-тын (1962) тәмамлый. 1951–57 елларда Совет армиясендә, 1956 да Венгриядәге вакыйгаларда катнаша. 1964 тән Одесса ун-тында, КПСС тарихы каф. мөдире (1972–92). Хезмәтләре Беренче бөтендөнья, гражданнар, Бөек Ватан сугышларына, СССР да 1930 еллардагы сәяси репрессияләргә карый. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Богдан Хмельницкий (Украина) орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Львов политехник ун-ты каршындагы Хәрби ин-т (Украина) терр-ясендә Я.ның бюсты, Карача-Елга а. мәктәбе бинасында мемориаль такта куелган.

Х е з м.: Революция и мир (Солдатские массы против империалистической войны, 1917 — март 1918 гг.). М., 1980); Весну принесли на знамёнах. Од., 1984; Первый Верховный главнокомандующий (О Н.В.Крыленко). Киев., 1989; Трагедия полководцев: Репрессии 1930–50-х гг. в СССР. М., 1992.

*Әд.:* Щ е т н и к о в В.П. Памяти Якупова Назыма Мухаметзяновича // Лукоморье: археология, этнология, история Юго-Западного Причерноморья. Од., 2009. Вып. 3; Башкирская энциклопедия. Уфа, 2011. Т. 7.
*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**ЯКУ́ПОВ** Николай (Камил) Якуп улы (15.3.1920, Минзәлә кантоны, хәзер Тукай р-ны Иштирәк а. – 1.2.1999 Чаллы ш.), Сов. Союзы Герое (15.1.1944), мед. хезмәте гв. подполковнигы. Чистай шәһәрендә мед. техникумын (1939), Казанда Респ-ка партия мәктәбен (1949) тәмамлый. Кама Тамагы р-нының Келәр авылында фельдшер булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. Совет-фин сугышында һәм 1939 да Көнбатыш Украинага һәм Көнбатыш Белоруссиягә совет гаскәрләре керүдә катнаша. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында. 189 нчы укчы дивизиянең 259 нчы укчы полкы, 112 нче Башкорт кавалерия дивизиясенең 275 нче кавалерия полкы, 61 нче армиянең 7 нче гв. кавалерия корпусының 58 нче гв. кавалерия полкы составында Калинин, Сталинград һәм Үзәк фронтларда барган сугышларда хәрби фельдшер буларак катнаша. 1943 нең 27 сентябрендә Нивки (Белоруссия ССРның Гомель өлкәсе Брагин р-ны) авылы



Н.Я.Якупов.

янында Днепр елгасын кичеп чыкканда батырлык күрсәтә: яралылар тулы көймә б-н 27 рейс ясый һәм 74 сугышчы һәм офицерны коткара, плацдармда сугышучылар өчен сугыш кирәк-яраклары алып чыга. 1946 дан запаста. Чаллы шәһәрендә яши, «Камдорстрой» трест идарәсе башлыгы урынбасары булып эшли. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Я. исеме Башкортстан Респ-касы Милли музеенда һәм Уфа шәһәрендә 112 нче Башкорт кавалерия дивизиясе музеенда урнаштырылган 112 нче Башкорт (16 нчы гв. Чернигов) кавалерия дивизиясе Сов. Союзы Геройлары мемориаль такталарына алтын хәрефләр б-н уелган. Чаллы шәһәрендә, Герой яшәгән йорт фасадына мемориаль такта куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЯКУ́ПОВ** Нух Мәхмүт улы (25.8.1950, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1995), проф. (2010), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2002). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), А.Н.Туполев тәҗрибә КБның Казан ф-лында эшли. 1978 елдан РФА КГҮдә: Физика-техника ин-тында (1991 гә кадәр), сүрүләрнең нәсызыкча механикасы лаб-ясе мөдире (1988 дән), Механика һәм машиналар төзү ин-тында, шул ук исемдәге лаб. мөдире (1991 дән). Хезмәтләре катлаулы геометрияле юка кормаларның нәсызыкча механикасына карый. Я. йөкләм астында коррозион ашалу моделен тәкъдим итә; коррозиягә магнит кыры б-н ультрашәмәхә нурланыш йогынтысын ачыклый. Катлаулы геометрияле сүрүләрне хисаплау өчен азакды элементлар алымы вариантын, катлаулы структуралы элпәләр ныклыгын тикшерүнең тәҗрибә-теоретик алымын эшли. Уйлап табуга 30 патенты бар. Медальләр, ш.и. халыкара күргәзмәләрнең алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Прикладные задачи механики упругих тонкостенных конструкций. К., 1994; Механика: проблема-идея-практика. К., 2010; Экспериментально-теоретический метод определения механических характеристик сферических плёнок и мембран со сложной структурой // Механика твёрдого тела. 2011. № 3 (автордаш).

**ЯКУ́ПОВ** Радик Альберт улы (7.12.1961, Уфа ш.), невропатолог, мед. фән. д-ры (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1985), Казан ГИДУВының (хәзер Казан мед. академиясе) нерв авырулары һәм рефлексотерапия кафедрасында эшли, 1987–90 елларда, бүлеп, Киев ГИДУВында. 2009 дан невропатология һәм рефлексотерапия каф. мөдире. Хезмәтләре периферик нерв системасы авырулары, психоэмоциональ тайпылышлар б-н бәйле рефлексотерапиягә карый. «Клиник медицинада миофасциаль авыртуның фундаменталь һәм гамәли аспектлары» хезмәте өчен ТРның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә лаек була (2006).

Х е з м.: Рефлексотерапия психоэмоциональных нарушений. К., 1992 (автордаш); Рефлексотерапия хронической боли при заболеваниях периферической нервной системы. К., 2004 (автордаш); Особенности количественных и качественных показателей мигательного рефлекса и патологической системы у больных тиком // Вестн. современной клинической медицины. 2017. Т. 10, № 3.

**ЯКУ́ПОВ** Радик Гыйззәт улы (31.12.1935, БАССРның Эстәрлетамак р-ны Ибрай а. — 22.2.2011, Уфа ш.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1986), проф. (1987), Башкортстан Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (1997). Уфа авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), Уфа шәһәре пр-тиесенең авиация моторлары тәҗрибә КБнда эшли, лаб. башлыгы (1961–68), 1968–73 елларда «Транснефть» фәнни-тикшеренү ин-тында (Уфа) проект баш инженеры. 1973 тән Уфа авиация техник ин-тында, машина детальләре һәм механизмнар теориясе каф. мөдире (1984–89), материаллар каршылыгы каф. профессоры (1989–2001). 2001 елдан РФА Уфа ГҮнең Механика ин-тында. Хезмәтләре деформацияләнгән каты җисем механикасы өлкәсенә карый. Дулкын йөкләнеше йогынтысында мохит б-н тәэсир итешкән кормалар динамикасын; магистраль торбаүткәргечләрнең ныклыгын һәм тотрыклыгын; өслекчә хәрәкәтчән йөкләнешләр тәэсирендәге җир асты корылмаларының юка диварлы динамикасын; металларны басым ярдәмендә эшкәрткәндә кораларның темп-расын һәм киеренке халәтен тикшерүләр үткәрелә. Я.ның хезмәтләре грунтларда шартлау дулкыннары таралу, аларның җир асты корылмаларына тәэсир ясау һәм шартлауның хәвефсезлек дистанцияләрен билгеләү буенча гамәли мәсьәләләрне хәл итү өчен теоретик нигез булып тора.

Х е з м.: Пластические деформации круглой пластины при нагружении взрывной волны // Прикладная механика и техн. физика. 1982. № 4; Динамика тонкостенных элементов подземных сооружений под действием взрывной волны. Уфа, 1994; Динамика конструкций, взаимодействующих со средой. М., 1995 (автордаш).

**ЯКУ́ПОВ** Рифкать Госман улы (29.7.1944, Ижевск ш.), фоторәссам, журналист. Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1971–73 елларда — «Яшь ленинчы», «Комсомолец Татарии» г-таларында, 1973 тән «Азат хатын» ж-лында фотохәбәрче. 1987 дән башлап (бүленеп) Г.Камал исем. Татар акад. театрында фотограф булып эшли. Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институты (1971), Казан консерваториясе (1978), ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы Халык иҗаты үзәге (2008–10) тарафыннан ТР авылларына (Казан арты, Минзәлә р-ны), РФдә татарлар тупланып яшәгән төбәкләргә (Киров өлкәсе, Әстерхан, Төмән, Уфа шәһәрләре һ.б.) оештырылган этнография һәм фольклор экспедицияләрендә катнаша. 1992–98 дә Кырымда эшли. 1996 да БМО миссиясе заказы буенча Кырымнан куылган халыклар (Кырым татарлары, болгарлар, әрмәннәр, греклар, немецлар) тормышы турында репортажлар төшерә. Ул Казан «Тасма» фотоклубын оештыручыларның берсе (1975), аның күргәзмәләрендә даими катнашучы. Журналистлар берлеге (1976), Россия фоторәссамнары берлеге әгъзасы (2001).

Татар проф. фотография мәктәбен үстерүгә зур өлеш кертә. Үзен документаль фотография остасы итеп таныта (КамАЗ, Түбән Кама шәһәре төзелешләреннән һ.б. фотолар), соңрак сәнгатьчә фотографиягә мөрәҗәгать итә. 1979 да «Сабантуй» фотоальбомын бастыра. Тематик фотографияләр сериясендә Идел-Урал буе, Кырым, Себер, Польша, Литва татарларының көнкүрешен, табигатен, этник типларын чагылдыра. Бу эшләре Я.ка илебездә дә, чит илләрдә дә зур уңыш китерә. «Казан» («Казань», 1976), «Совет Татарстаны» («Советский Татарстан», Мәскәү, 1978), «Башка төрле Россия» («Другая Россия», Оксфорд, 1986), «Башка төрле күрүчеләр» («Инаковидящие,» Хельсинки, 1988), «Үзгәрүчән чынбарлык» («Меняющаяся реальность», АКШ, Рочестер ш., 1991), «Г.Ка-







Р.Г.Я к у п о в. 1. «Авыл карты». 1978; 2. «Тбилисида якшәмбе көн». 1984; 3. «Иске Татар бистәсе» сериясеннән. 2002.

мал исем. театр» («Театр им. Г.Камала», 1996), «Азнакай тамчылары» (2000), «Мең кыяфәтле Казан» («Казань тысячеликая», 2005), «Татарстан — уртак йортыбыз» («Татарстан — общий дом», 2007), «Татар театрына — 100 ел» («100 лет Татарскому театру», 2009) альбомнарындагы фотолар авторы.

Я. иҗатында Кырым татарлары темасы аерым урын алып тора: «Газаплы кайту хроникасы» («Хроника трудного возвращения», 1992–98) циклы, «Кырым. Югалтулар һәм табышлар» («Крым. Потери и приобретения», 1995), В.Якупованың «Кырым татарлары, яки Сталиннан сәлам!» («Крымские татары, или привет от Сталина!», 2002) китабындагы фоторәсемнәр.

Журналистларның халыкара «Уорлдпрессфото» фотоконкурсында (Нидерланд, Гаага ш., 1978), Оксфордта (Англия, 1986), Хельсинкида (Финляндия, 1988), Нью-Йоркта (АКШ, 1991) һ.б. халыкара заманча фотография күргәзмәләрендә катнаша.

Шәхси күргәзмәләре 1990 да (Финляндия, Тампере ш.), 1991 дә (Швеция, Стокгольм), 1994 тә (Польша, Люблин ш.), 1995 тә (Германия, Берлин), 1997 дә (Австрия, Пертшахам, Вертерзее шәһәрләрендә), 2005 (Финляндия, Хельсинки), 2006, 2011 дә (икесе дә — Казан) үткәрелә.

Журналистларның респ-ка «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» конкурсы лауреаты (2002).

Әсәрләре С.-Петербургтагы Россия этнография музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Стокгольмдагы, Берлиндагы этнография музейларында, Нью-Йорктагы «Коркоран» галереясында һ.б.да саклана.

*Әд.:* Ш а р и п о в В. Сабантуй, который всегда с нами // Советское фото. 1980. № 7; К у т у й Р. Лики мгновений // Казань. 2003. № 3; К о л и н а С. Поиски и находки Рифа Якупова // Казань. 2011. № 5. *Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЯКУ́ПОВ** Таһир Габдулла улы (13.5.1946, Казан — 1.10.1999, шунда ук), җырчы (тенор), ТАССРның атказ. артисты (1977). 1964–73 елларда ТАССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты. 1974 тән Татар филармониясенең эстрада бүлеге солист-вокалисты. Җырчының тавышы аһәңле, йомшак тембрга ия; башкаруы төгәл дикциясе, эмоциональлеге һәм сәнгатьчәлеге, әсәрләренең эчтәлеген тирәнтен ачу осталыгы б-н аерылып тора. «Олы юлның тузаны», «Туган тел», «Наласа авылы көе», «Тәзкирә», «Зөләйха», «Уел», «Хафизәләм-иркәм», «Карачтау авылы көе» һ.б. җырларны башкарып, халык мәхәббәтен казана. Респ-ка радиосы һәм телевидениесеннән чыгышлар ясый (ТР ДТРКсында 40 ка якын фонд язмасы саклана), Россиядә һәм чит илләрдә концерт эшчәнлеге алып бара.



Т.Г.Якупов.

*Әд.:* С а л ь м у ш е в Р. Җырларыңда безне юаттың...: Татарстанның атказанган артисты Таһир Якупов турында истәлекләр. К., 2004; А р с л а н о в а Ф. Государственный ансамбль песни и танца Республики Татарстан. К., 2007.

**ЯКУ́ПОВ** Тәлгать Равил улы (29.8.1964, Саба р-ны Өчнарат а.), биохимик, вет. фән. д-ры (2012). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнан соң (1986), шунда ук биол. һәм нәорганик химия кафедрасында эшли, бер үк вакытта, 2000–03 елларда, проректор. Хезмәтләре мөгезле эре терлекләрдә туберкулёз авыруына диагноз кую, махсус профилактика уздыру һәм дәвалау ысуллары һәм чараларын эшләүгә карый.

Х е з м.: ПЦР в диагностике туберкулёза крупного рогатого скота // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 2001. Т. 173 (автордаш); Новые подходы в диагностике лейкоза крупного рогатого скота // Уч. зап. КГАВМ. 2010. Т. 204; Иммуноблот анализ в диагностике туберкулёза // Вет. врач. 2011. № 1.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

**ЯКУ́ПОВ** Фәрват Габдулла улы (20.3.1958, БАССРның Гафури р-ны Бурлы а. – 1.12.2008, Мәскәү өлкәсенең Видное ш., туган ягында җирләнә), РФ Герое (25.8.1995), милиция өлкән лейтенанты. ДОСААФ Уфа техник мәктәбен (1976), РФ Эчке эшләр министрлыгының Мәскәү юридик ин-тын (2000), РФ Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте академиясен (Мәскәү, 2007) тәмамлый. 1976–91 елларда Совет Армиясендә, 1983–85 тә СССР Кораллы көчләрендә, совет гаскәрләренең Әфганстан Демократик Респ-касындагы чикләнгән контингенты составында хезмәт итә. 1991–2002 дә РФ Эчке эшләр министрлыгының Мәскәү өлкәсе эчке эшләр баш идарәсендә, махсус максаттагы милиция отряды отделениесе командиры, 1993–95 тә аеруча әһәмиятле эшләр буенча тиз хәрәкәт итүче махсус отряд өлкән оператив уполномоченные, 1996–2002 дә Оешкан җинаятьчелек б-н көрәш региональ идарәсенең оператив-тактик әзерлек үзәгендә. Берничә тапкыр Төньяк Кавказда хезмәт командировкаларында була. 1995 нең гыйнварында Чечен Респ-касы терр-ясендә оешкан кораллы төркемнәр б-н сугышчан контртеррористик операция барышында батырлык күрсәтә: махсус отряд бандит төркемнәренең 10 нан артык әгъзасын әсирлеккә төшерә, дошман якның урнашкан урыны, ныгытмалары һәм яшерен ут позицияләре турында әһәмиятле мәгълүмат ала. Чираттагы сугышта, чолганышка эләккән Россия солдатлары төркемен йолып алып, авыр яралана. 2003 тән отставкада. Видное шәһәрендә яши. Батырлык, «Шәхси батырлык өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*М.З.Хәбибуллин.*





Ф.Г.Якупов. Х.Г.Якупов.

**ЯКУ́ПОВ** Харис Габдрахман улы (23.12.1919, Казан — 17.2.2010, шунда ук), нәкышьче, график, педагог, Россия САнең хакыйкый әгъзасы (1997, 1973 елдан СССР САнең мөхбир әгъзасы), РСФСРның, СССРның халык рәссамы (1963, 1980), РСФСРның, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлый (1939). 1946 да Мәскәүдәге «Всекохудожник» Үзәк студиясендә Б.В.Иогансонда шөгыльләнә. Казанга әйләнеп кайтканнан соң (1946 дан), Сәнгать фондында эшли. 1948–51 дә Казан сынлы сәнгать уч-щесендә укыта. 1976–2007 дә САнең Казандагы остаханәсенә җитәкчелек итә. ТАССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1947) һәм рәисе (1951–75). Респ-каның әйдәп баручы рәссамнарыннан берсе, соц. реализм юнәлешенең танылган вәкиле. Татар совет рәсем сәнгате мәктәбен булдыруга зур өлеш кертә, тарихи-революцион (нигездә, «ленинина»), хәрби-патриотик, көнкүреш һәм портрет жанрларында сюжетлы тематик картиналар иҗат итә. Я.ның картиналары арасында аеруча билгелеләре — «Сталин Туруханда сөргендә» (1951), «Хөкем алдыннан» (1954), «Ана портреты» (1955), «Герой-ананы данлау» (1957), «Иделдә яз» (1959); «Ирекккә очу (Михаил Девятаев батырлыгы)» (1964–71) триптихы; «М.Вахитов исемендәге колхоз алдынгылары» (1960–65) портретлар сериясе, «Пролог» (1969), «Татарстан алтыны» (1974), «Татарстан АССРга Халыклар дуслыгы ордены тапшыру» (1977, А.М.Родионов б-н бергә), «Ф.Ә.Табиев портреты» (1978), «Казан студентлары. 1887 ел» (1980), «Рәссам. Фронт юллары», «Минем шәлелеләрем» (икесе дә — 1985), «Габдулла Тукай истәлегенә» (1986) триптихы, «Полкташым пулемётчы кыз М.Щербак» (1991), «Җиңү көне» (2004) триптихы, «Сугыш иде (төп көчләр һөҗүмгә бара)» (2005). Натурадан төшерелгән «Кызыл Байрак яныңда Идел» (1939), «Казансу елгасында ташу» (1948), «Чулман елгасында боз китү» (1958), «Май башы» (1964), «Кар иртә төште» (1980), «Март башы» (1984) пейзажлары; Төньяк Кореяда (1959), Италиядә (1960; 1971–72), Кавказда (1962), Кырымда (1972) һ.б.да язылган этюдлар сериясе авторы.

Станлы графикада әсәрләр иҗат итә: 1941–45 тәге фронт рәсемнәре сериясе (якынча 250 рәсем); «В.Маяковский Казанда. 1914» (1968), «Г.Тукай һәм Ф.Шаляпин» (1970), «Г.Державин Болгарда» (1972) сюжетлы композицияләре; мәдәният әһелләре Ф.Яруллин,























Х.Г. Я к у п о в. 1. «Хөкем алдыннан» (Татар шагыйре М.Җәлил 1944 елда Берлинның Моабит төрмәсендә). 1954; 2. «Советлар Союзы Герое М.П.Девятаев портреты». 1971; 3. «Рәссам. Фронт юллары». 1985; 4. «Татарстан алтыны». 1974; 5. «Көчле кешеләр» (Яшь сыер савучылар Ф.Гәрәева, М.Исламова һәм С.Сәгъдиева). 1963–64; 6. «Пролог». 1969; 7. «Габдулла Тукай истәлегенә». 1985–86; 8. «Сыер савучы Хәтирә Садыйкова». Картон. Майлы буяу. 1963; 9. «Кызыл миләш». Картон. Майлы буяу. 1984; 10. «Көнбагышлар». Картон. Майлы буяу. 1989; 11. «Һөнәрле үлмәс» татар халык әкиятенә иллюстрация. Кәгазь. Акварель. 1957. 1, 2, 3, 4, 5, 7, 8, 9, 10 – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда; 6 – «Казан» милли мәдәният үзәгендә.

Х.Әбҗәлилов, К.Тинчурин (барысы да — 1966) һ.б. портретлары; пастель, темпера, акварель, соус техникасында башкарылган пейзажлар һ.б. Г.Тукайның Татгосиздатта басылган «Гали белән кәҗә», М.Гафуриның «Шигырьләр һәм мәсәлләр» (икесе дә — 1947), Ә.Фәйзинең «Пугачёв Казанда» (1951), А.С.Пушкинның «Әкиятләр» (1953) китапларына илл. ясый. «Чаян» ж-лында басылган сатирик рәсемнәр, сәяси плакатлар авторы.

1939 дан респ-ка, 1943 тән төбәкара, 1964 тән «Зур Идел»; 1949 дан РСФСР автономияле респ-калары рәссамнары, 1960 тан «Совет Россиясе» бөтенроссия күргәзмәләрендә (Мәскәү); бөтенсоюз сәнгать күргәзмәләрендә — (1949, 1950, 1951, 1955, 1957, 1961), «Совет хакимиятенә 50 ел» (1967), «СССР Сәнгать академиясе әгъзалары әсәрләре күргәзмәсе»ндә (1973, 1979), «Хезмәткә дан!» (1976), «Без коммунизм төзибез» (1981); «Совет сынлы сәнгате Финляндиядә» (1950) күргәзмәләрендә (Мәскәү); Польшада, ГДРда һәм Югославиядә совет рәссамнары әсәрләре (1965), Франциядә совет сәнгате (1977) һ.б. халыкара күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1948, 1990, 2005, 2009 да (Казан), 1983 тә (Батуми ш.) үткәрелә. 1971–74 тә ТАССР ЮС депутаты.

«В.И.Ленин Татарстан АССР төзү турындагы Декретка кул куя» (1950; Л.Ә.Фәттахов б-н бергә) картинасы өчен 3 нче дәрәҗә Сталин премиясе, «Алдынгы терлекчеләр — көтүчеләр Н.Җиһаншин, Ш. һәм Г.Шакировлар» (1963–64), «Чаллы гүзәлләре» (1975) картиналары өчен РСФСРның И.Е.Репин исем. Дәүләт премиясе (1976), «Татар халык әкиятләре»нә илл. сериясе (1957, Л.Ә. Фәттахов б-н бергә) өчен ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе бирелә.

Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе», 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәрләре Мәскәүдә Третьяков галереясында, Шәрекъ халыклары сәнгате музеенда, В.И.Ленин музеенда (Дәүләт тарих музее ф-лы), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Чаллы шәһәре картиналар галереясында, Бурят ССР Сынлы сәнгать музеенда, Чуаш Дәүләт сәнгать музеенда, Пхеньян шәһәрендәге Сынлы сәнгать музеенда (Төньяк Корея) һ.б.да саклана.

«Хәзинә» Милли сәнгать галереясында Я. әсәрләренең даими экспозиция залы ачыла. Я.ның скульптур портретларын А.Х.Әбдрәшитов (1980, бронза), Ф.Г.Гайнуллов (1983, гипс) ясый.

Х е з м.: Рәсем — мәхәббәтем минем. К., 2000; В стране Чхонлима: Корейские зарисовки. М., 1968; Фронтовые зарисовки: Записки художника. К., 1981; Легко ли стать художником: время, искусство, творчество. К., 2004; Путешествие художника вокруг Европы. К., 2009.

*Әд.:* Ч е р к а с о в а Н. Харис Якупов. М., 1960; Ф а й н б е р г А. Сильные люди // Художник. 1970. № 7; Ч е р в о н н а я С.М. Харис Якупов. Л., 1983; ш у л у к. Палитра века на якуповском холсте // Татарский мир. 2009. № 3.

*Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЯКУ́ПОВ** Эдуард Закирҗан улы (17.4.1967, Ульянов ш.), невропатолог, мед. фән. д-ры (2007). Ижевск мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1990), Казан мед. ин-тының нерв авырулары кафедрасында эшли. 1990 елдан дәвалау эшләре буенча проректор, бер үк вакытта, 2009 дан, мед. генетикасы курслы неврология каф. мөдире. Хезмәтләре вегетатив дисфункция синдромы очрагында интегратив системалар халәтен бәяләүгә, паника һөҗүмнә дучар авыруларны дәвалау өчен транскраниаль магнит стимуляциясе куллануга карый.

Х е з м.: Синдром повышенной нервно-мышечной возбудимости при вегетативной дисфункции // Неврол. вестн. 1995. Вып. 1/2 (автордаш); Состояние цереброваскулярной реактивности и зрительные вызванные потенциалы у больных с вегетативными кризами при различной скорости пассивного трансмембранного ионотранспорта // Неврол. вестн. 2005. № 1/2 (автордаш); Взаимосвязь между нарушениями сна, эмоциональным состоянием и когнитивными нарушениями // Неврол. вестн. 2017. № 1 (автордаш).

**ЯКУ́ПОВА** Аида Альберт кызы (29.7.1968, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (2012). Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1991), шунда ук невропатология, нейрохирургия һәм мед. генетикасы кафедрасында эшли. Хезмәтләре пароксузмаль булмаган хроник баш авыртуын өйрәнүгә, диагноз кую һәм дәвалау ысулларын эшләүгә карый.

Х е з м.: Рефлексотерапия цервикальной головной боли // Неврол. вестн. 2004. Вып. 1–2 (автордаш); Опыт применения левицирацетама в терапии мигрени без ауры // Казан. мед. журн. 2006. № 6; Рефлексотерапия хронической невропатической боли. Ч. 1. Общие положения // Альтернативная медицина. 2007. № 1; Превентивная рефлексотерапия хронической головной боли // Неврологический вестн. Журнал им. В.М.Бехтерева. 2011. Т. XLIII. Вып. 3.

**ЯКУ́ПОВА** Венера Габдулла кызы (6.7.1959, Яшел Үзән р-ны Кызылъяр а.), журналист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1995). Казан ун-тын (1981), ВЛКСМ ҮКның Югары комсомол мәктәбен (1986) тәмамлый. 1981–84 елларда «Зеленодольская правда» (Зеленодольск ш.) г-тасында хәбәрче булып эшли. 1986 дан «Молодёжь Татарстана» г-тасында хәбәрче, бүлек мөдире, мөхәррир урынбасары. 1995 тән *«Казанские ведомости»* г-тасы баш мөхәррире. Мәкаләләре «Идел», «Ялкын» ж-лларында, «Татарстан яшьләре», «Известия Татарстана» г-таларында басыла. «Суверенитет турында йөз хатирә»(«100 историй о суверенитете», 2000), «Кырым татарлары, яки Сталиннан сәлам!» («Крымские татары, или Привет от Сталина!», 2009) исемле китаплар авторы. ТРның Журналистлар берлеге бүләге лауреаты (1990, 2001). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЯКУ́ПОВА** Зәйнәп Нәҗип кызы (18.3.1913, Оренбург өлкәсенең Бозаулык ш. — 6.10.1985, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1962), проф. (1969), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1982), ТАССРның атказ. табибе (1964). Проф. П.В.Маненков шәкерте. 1936 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый, 1941 дә Казан мед. ин-тының дәвалау ф-тын тәмамлаганнан соң, 1 нче акушерлык һәм гинекол. кафедрасында калдырыла; шул ук елда Казан гарнизонының хәрби-табиблек комиссиясе рәисе итеп билгеләнә, бер үк вакытта Казан мед. ин-тының сан.-гигиена ф-ты деканы урынбасары, ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы поликлиникасы табибе. 1947 дән Казан мед. ин-тының 2 нче акушерлык һәм гинекол. кафедрасында, 1969–84 тә шул ук каф. мөдире. Хезмәтләре гинекол. тайпылышларны дәвалауга, бала тудырганда кан китү очракларын кисәтүгә, аналык контрацепциясе ысулларына карый. Я. — атопик кан китү очракларын кисәтү, йөклелекнең 32 нче атнасында карындагы яралгының авырлыгын билгеләү ысуллары авторы, «гормональ кыскычлар» куллануны гамәлгә кертүче. Аның тәкъдиме б-н 1970 елларда Казанда «Йөклелек профилактикасы үзәге» оештырыла. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Уйлап табуга 4 патенты бар.

Х е з м.: Методы стимуляции родовой деятельности при раннем отхождении вод // Казан. мед. журн. 1965. № 3; Влияние внутриматочной контрацепции на неспецифическую реактивность организма женщин // Акушерство и гинекология. 1977. № 12; Ультразвуковое исследование скорости кровотока в общих сонных артериях для диагностики нарушений мозгового кровообращения у новорожденных // Акушерство и гинекология. 1982. № 1.

*Әд.:* Профессор Зайнаб Назиповна Якубова // Казан. мед. журн. 1986. № 1.

**ЯКУ́ПОВА** Наилә Мәлик кызы (15.9.1955, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2004), проф. (2006). ТРның атказ. икътисадчысы (2006). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1976), 1977 елдан шунда ук эшли. 2007 дән җитештерү икътисады, 2010 нан кризиска каршы идарә һәм бәяләү эшчәнлеге кафедралары мөдире. Хезмәтләре пр-тие бәяләре б-н идарә итүгә, куркыныч янау очраклары һәм инвестицияләргә карый.

Х е з м.: Венчурные инвестиции: стратегия, принципы, инструменты. К., 2003 (автордаш); Стратегическое управление стоимостью предприятия. К., 2003; Контролинг рисков: выявление, дифференциация, предупреждение. К., 2009 (автордаш); Инвестиционная привлекательность: анализ, измерение, оценка. К., 2010 (автордаш).

*Ф.С.Зыятдинов.*

**Я́КУШЕВ** Илгизәр Галәлетдин улы (15.3.1946, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1988), проф. (1992), РФнең атказанган уйлап табучысы (1990), ТРның атказанган химигы (1997). Казан химия-технол. ин-тын (1972), Мәскәү идарәчелек академиясен (1984), Токио уку-укыту үзәген (Япония, 1999) тәмамлый. 1965–94 елларда Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (бүлек башлыгы, баш конструктор, 1989 дан ген. директор урынбасары). 1994 тән «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖдә (ген. директор урынбасары), бер үк вакытта Казан технол. ун-тында (2000 нән). Хезмәтләре махсус химиягә һәм нефть химиясенә карый. Я. көпшә системаларындагы коргыларның аномаль яну процессының формалашуы һәм үсеше шартларын билгели,

аларны конструкцияләү методикаларын тәкъдим итә. Махсус кулланышлы эшләнмәләрне, янгын сүндерү импульслы системаларын, нефть химиясе кәсәбәләрендәге калдыкларны һәм нефть эшкәртү нәтиҗәсендә хасил булган авыр калдыкларны эшкәртүнең технологияләрен эшләүдә катнаша. Я. катнашында ТРның нефть-газ химиясе тармагы, биотехнологиясе, фарм. сәнәгате концепциясе һәм үсеше программалары (2005–15 еллар өчен) булдырыла. Фәнни тикшеренү нәтиҗәләре ТРның, РФнең оборона, нефть химиясе сәнәгате пр-тиеләрендә кулланыла. Уйлап табуга 112 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын, бронза медальләре, Халыкара күргәзмәнең (Брюссель, Бельгия) көмеш медале б-н бүләкләнә.

**ЯКУШЕ́НКО** Николай Иванович (29.11.1897, Калуга ш. — 8.2.1971, Казан), драма актёры, педагог, ТАССРның, РСФСРның һәм СССРның халык артисты (1939, 1950, 1955). Калуга гимназиясен тәмамлаганнан соң, Киев коммерция ин-тының икътисад ф-тында, бер үк вакытта Н.П.Смурский җитәкчелегендәге «Соловцов» театры каршындагы студиядә укый. Укуын тәмамлаганнан соң, Киевта 2 нче драма театры актёры; Калуга, Тула, Омск, Новосибирск, Брянск, Архангельск, Ярославль шәһәрләрендәге театрларда эшли; 1935 елдан Казан Зур драма театрында. Казанга реж. И.А.Ростовцев чакыруы буенча килә. Я.ның беренче Бессеменов («Мещаннар», М.Горький) роле театр тормышында сизелерлек вакыйга була, актёр героеның рухи дөньясын, характер үзенчәлеген тирәнтен ача. Я. Казан театры сәхнәсендә рус театр сәнгате тарихына кергән зур рольләр башкара: Хлестаков («Ревизор», Н.В.Гоголь, 1939, 1944), Чичиков («Үле җаннар», Н.В.Гоголь, 1952), Лука, Карт («Тормыш төбендә», 1949; «Карт», 1956; М.Горький). Ул иҗат иткән Аким («Караңгылык хакимлеге», Л.Н.Толстой, 1959) образы халык намусын гәүдәләндерә, әхлакый күрсәткеч булып тора. Я.ның Дергачёв, Аркашка Счастливцев, Шмага («Соңгы корбан», «Урман», «Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Вафля («Ваня абзый», А.П.Чехов), Мармеладов («Җинаять һәм җәза», Ф.М.Достоевский романы буенча), Кузовкин («Әрәмтамак», И.С.Тургенев) рольләрендә җәмгыять тарафыннан кыерсытылган һәм түбәнсетелгән, әмма кешелек сыйфатларын җуймаган «кечкенә кеше» образы гәүдәләндерелә. Ул башкарган үзсүзле, дуамал һәм ялган исем йөртүче Градобоев, Мамаев («Ялкынлы йөрәк», 1943; «Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», 1946; А.Н.Островский) образлары фаш итү көченә ия нәфрәт тулы сарказм б-н сугарылган. Кайнар темпераментка ия булу, рольнең асылына тирәнтен үтеп керү сәләте Я.га Фёдор патшаның («Фёдор патша», А.К.Толстой, 1940, 1955) сәяси көчен югалту фаҗигасен, күңел газапларын тамашачы игътибарына төгәл җиткерү мөмкинлегенә бирә.

Я. совет драматургиясе образларын тудыруга зур өлеш кертә. Юл күзәтчесе Влас («Ерак», А.Н.Афиногенов), хисапчы Рыдай («Павел Греков», Б.И.Войтехов, Л.С.Ленч), Пикалов («Любовь Яровая», К.А.Тренёв), комиссар Лукин («Батырлык», Г.Берёзко), академик Верейский («Намус законы», А.П.Штейн), профессор Туляга («Кем соңгы булып көлә?», К.Крапива) образлары Я. башкаруында



Н.И.Якушенко.

тормышчан, теге яки бу вакыйгага мөнәсәбәтләре, совет чоры кешесенең дөньяга карашы б-н ышандырырлык итеп ачылалар; хәрәкәтләр һәм интонацияләр төгәллеге б-н аерылып торалар. Ул уйнаган Фаюнин («Ябырылу», Л.М.Леонов, 1943) образы иң явыз фигура буларак гәүдәләнә, Америка сенаторы Мэрфи («Русча сорау», К.М.Симонов, 1947) әдәпсезлеге, оятсызлыгы б-н тетрәндерә. Я. иҗат иткән замандашлар образлары галереясында Щукарь бабай («Күтәрелгән чирәм», М.А.Шолохов романы буенча, 1963) аерым урын били. Бу образ аша актёр тарихи борылыш чигендә Россиядә крәстияннәрнең авыр тормышын, шул ук вакытта аларның төрле шартларга яраклаша һәм кирәк булганда аннан хәтта файда таба белү осталыгын, зирәклеген ача. Я. башкарган Сиражетдин («Банкрот», Г.Камал, 1940), Кәбир Галимуллин («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт, 1950), Алмашев («Үлмәс җыр», Р.Ишморат, 1956) рольләре характерның милли үзенчәлекләрен тирәнтен тоеп, сатирик үткенлек б-н оста гәүдәләндерелүләре б-н аерылып тора.





Н.И.Якушенко: 1. Фёдор патша (шул исем. әсәр буенча, А.К.Толстой); 2. Карт (шул исем. әсәр буенча, М.Горький) рольләрендә.

Актёр концертларда, иҗат кичәләрендә, радиодан еш чыгышлар ясый. 1943–61 дә — Казан Зур драма театры каршындагы студиядә, 1959–69 да Казан консерваториясендә сәхнә теле һәм нәфис сүз укыта. Казанның һәм респ-каның театр сәнгате һәм мәдәни тормышы үсешенә йогынты ясый, театр сәнгатен актив пропагандалый, иҗади яшьләргә остаз була, матбугатта язышa. 1947–59, 1963–67 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, ике «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә. Казанда Я. яшәгән йортта мемориаль такта урнаштырылган.

*Әд.:* З и л ь б е р м а н Е. Николай Иванович Якушенко: Творческий портрет актёра. К., 1948; ш у л у к. Н.Якушенко: Заметки о творчестве актёра. К., 1957; Актёр и гражданин: Статьи, воспоминания, письма. К., 1979; Народные артисты. К., 1980; И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991; Б л а г о в Ю. В одном ряду с великими // Качалов и качаловцы. К., 2008. Ч. 1.

*Ю.А.Благов.*

**ЯКУ́ШКИН** Николай Михайлович (7.7.1953, Тәтеш р-ны Пролей-Каша а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2005), проф. (2006), ТРның атказ. икътисадчысы (1998). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), Тәтеш р-ны «Дружба» к-зында икътисадчы, баш икътисадчы булып эшли. 1978–87, 1990–93 елларда Казан а.х. ин-тында укыта. 1987–90 да КПСС өлкә ком-тында, 1993–94 тә ТР Президенты Аппаратында референт, 1994–2013 тә ТР а.х. һәм азык-төлек министры урынбасары. 2013 тән Татарстан агробизнес кадрларының белемен күтәрү ин-ты ректоры. Хезмәтләре а.х.нда аграр сектор үсешен икътисади көйләү һәм матди стимуллаштыру мәсьәләләренә карый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Аграрный сектор Татарстана в условиях рыночной экономики. К., 1997; Экономическое воздействие государства на развитие аграрной сферы: вопросы теории и практики. К., 2004; Материальное стимулирование в сельском хозяйстве. М., 2010; Возможности адаптации сельхозпредприятий к рискам // АПК: экономика, управление. 2014. № 6.

*Әд.:* М и р о ш н и к о в В. О времени и о себе // Лидер Татарстана. 2008. № 9.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ЯКУ́ШКИНО** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Аксумла суы буенда. 2010 елда 549 кеше (чуашлар) яши. Халыкның төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Ускунла, Аксумла исемнәре б-н

билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. Я.да земство мәктәбе (1896 да ачыла), 2 ярма яргыч, май язу йорты, 2 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2538 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Октябрь (1997 нең декабреннән Нурлат) р-нында. Халык саны: 1859 да — 649, 1897 дә — 997, 1908 дә — 1071, 1920 дә — 1313, 1926 да — 1059, 1938 дә — 1345, 1949 да — 1031, 1958 дә — 874, 1970 тә — 860, 1979 да — 706, 1989 да — 549, 2002 дә — 561 кеше.

**ЯКШУ́Р-БОДЬЯ́ РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* үзәк өлешендә урнашкан. 1929 елның 15 июлендә оештырыла. Мәйданы — 1778,4 *км*². Үзәге — Якшур-Бодья авылы (Ижевскидан 42 *км* төньяктарак). Халкы — 21674 кеше (2017). Татарлар саны: 1970 тә — 476, 1979 да — 438, 1989 да — 471, 2002 дә — 432 кеше. Алар, тупланып, Лынга (129 кеше), Чур (123), Якшур-Бодья (83) авылларында яшиләр. Район терр-ясенә татарларның күпләп күченүләренең сәбәбе — 1930 елларда совет хакимиятенең динне һәм кулакларны бетерү сәясәте. Миграциянең икенче дулкыны 1950–70 елларда райondагы урман сәнәгате үсеше б-н бәйле. Татар мәдәни оешмасы эшли (2006 дан), ел саен район *Сабан туе* уздырыла.

**ЯКЫНЧАЛЫ́К ТЕО́РИЯСЕ** (аппроксимацияләр теорисе), төрле матем. объектларны (функцияләр, интеграллар, функционаллар, операторлар, фәзалар, өслекләр, тигезләмәләр, аларның чишелешләре һ.б.) башка, кагыйдә буларак, гадирәкләре аша якынча күрсәтү. Я.т.нең иң эшләнгәне — функцияләр Я.т. төрле классларындагы функцияләрне алгебраик һәм тригонометрик полиномнар, вакламa-рациональ функцияләр, сплайннар һ.б. шундый гади һәм хисаплау өчен җайлы функцияләр аша якынча күрсәтү мәсьәләләрен карый.

Кешеләр якынчалаштыру б-н борынгы заманнан ук шөгыльләнә. Я.т. фән буларак, нигездә, рус математигы һәм механигы П.Л.Чебышев һәм немец математигы К.Вейерштрасс хезмәте нәтиҗәсендә 19 йөзнең 2 нче яртысында формалаша. Я.т.нең формалашуы һәм үсешенә математиклар С.Н.Бернштейн, Н.Н.Лузин, А.Н.Колмогоров, С.М.Никольский, С.Л.Соболев, П.Л.Ульянов, С.Б.Стечкин, К.И.Бабенко, Н.П.Корнейчук, В.К.Дзядык, А.Ф.Тиман, В.М.Тихомиров, Ю.Н.Субботин һ.б. өлеш кертәләр; Я.т.нең күп кенә бүлекләре, ш.и. функцияләрне һәм функция классларын күпбуыннар һәм сплайннар б-н якынчалаштыру, бер үлчәнешле һәм күп үлчәнешле интеграллар аркасында хасил булган сызыкча функционалларны якынчалаштыру төгәлләштерелә.

Татарстанда Я.т. өлкәсендәге тикшеренүләрне 20 йөз уртасында Казан ун-ты профессоры Б.М.*Гагаев* башлап җибәрә, аның шәкертләре С.Н.Андрианов, К.М.Шайдуков, А.Л.Кузьмин, Б.Г.*Габделхәев* аларны дәвам итәләр. 1970 еллардан тикшеренүләр оператор һәм төрле класстагы интеграль тигезләмәләрне чишүнең нәтиҗәле чикле якынчалыкларын эшләү кысаларында алып барыла. Нормалаштырылган фәзалардагы оператор тигезләмәләрне чишүнең иң яхшы чикле якынчалыклары теориясе төзелә; бу теория нигезендә төрле класстагы (регуляр һәм сингуляр, сызыкча һәм нәсызыкча, бер үлчәнешле һәм күп үлчәнешле, корректлы һәм корректсыз) интеграль һәм интегродифференциаль тигезләмәләрне чишүнең туры алымнарын оптимальләштерү проблемасы эшләнә. Түбәндәге бурычлар үтәлә: априори бирелгән мәгълүмат нигезендә бер яисә күп үзгәрмәнең иярмә функцияләрен оптималь торгызу һәм якынчалаштыру; функцияләрне Гельдер, Соболев, Никольский һәм Зигмунд фәзаларындагы тригонометрик күпбуыннар һәм минималь кимчелекле полиномик сплайннар аша якынчалаштыру; көчсез сингуляр, сингуляр һәм гиперсингуляр интеграль тигезләмәләрне чишүне күпбуыннар һәм сплайннар аша якынчалаштыру; интеграль һәм интегродифференциаль тигезләмәләрне чишүне осциллирлаучы функцияләр алымы б-н функциональ фәзаларның теориясендә һәм кушылмаларда иң еш кулланылган тигезләмәләргә якынчалаштыру; өзелешле полиномик һәм сплайн операторлары нигезендә төзелгән функцияләрне Лебегның иркеле күрсәткечле нормалаштырылган фәзаларда интеграль тигезләмәләрне чишүнең кушылмаларына якынчалаштыру. Бу төр тигезләмәләре өчен билгеле бер дәрәҗәдә яхшырта алмаслык һәм соңгы нәтиҗәләр алына. Ш.и. аларның чишелешләрен табу өчен иң югары төгәллек дәрәҗәсенә ия оптималь полиномиаль һәм сплайн якынчалык алымнары эшләнә; аларны эшләгәндә минималь санда арифметик операцияләр кирәк була.

*Әд.:* Г а г а е в Б.М. Исследование по теории ортогональных функций в Казанском университете // Уч. зап. Казан. ун-та. 1955. Т. 115, №10; ш у л у к . Работы Казанских математиков по ортогональным системам // Успехи мат.наук. 1957. Т. 12, №4; Г а б д у л х а е в Б.Г. Оптимальные аппроксимации решений линейных задач. К., 1980; ш у л у к. Прямые методы решения сингулярных интегральных уравнений первого рода. К., 1994.

*Б.Г.Габделхәев.*

**ЯЛА́ЛОВ** Фәрит Габделгазиз улы (11.4.1951, БАССРның Илеш р-ны Сеңрән а.), педагог, пед. фән. д-ры (2001), проф. (2003), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). Бөре пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), БАССРның Илеш р-ны Рсай урта мәктәбе директоры булып эшли. 1983 елдан Түбән Кама мәктәпләрендә директор, 1991 дән 2 нче татар гимназиясе директоры. 1997 дән Түбән Кама муниципаль ин-тының пед. кафедрасында, бер үк вакытта проректор, 2000 нән ректор. 2015 тән ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-тында директорның фән буенча урынбасары. Хезмәтләре этнопедагогика, этнодидактика мәсьәләләренә карый. Я. башлангычы б-н һәм аның җитәкчелегендә Түбән Камада ел саен этнодидактика буенча бөтенроссия һәм халыкара фәнни-гамәли конференцияләр уздырыла (2013 тә 11 нче Халыкара конференция үткәрелә).



Ф.Г.Ялалов.

Х е з м.: Инновацияле милли университет концепциясе. К., 2005; Национальные гимназии России: Концептуальные модели. М., 2001; Национальные гимназии России: Инновационный опыт. Нижнекамск, 2001; Этнодидактика. М., 2002; Профессиональная многомерность. К., 2013.

**ЯЛА́Н ЗӘЙ** посёлогы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 10 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2010 елда 117 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1880 елларда нигез салына. Халкы игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 416 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Яңа Писмән волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1889 да — 107, 1900 дә — 94, 1910 да — 116, 1920 дә — 305 (Тәкмәк авылын да кертеп), 1926 да — 198, 1938 дә — 123, 1949 да — 67, 1958 дә — 75, 1970 тә — 99, 1979 да — 72, 1989 да — 45, 2002 дә — 113 кеше.

**ЯЛАНТА́У** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 72 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 645 кеше (руслар) яши. Халыкның төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ташлы, Салкынчишмә исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерчелек һәм он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да Михаил-Архангел чиркәве, земство мәктәбе (1884 тә ачыла), 5 тегермән, 3 тимерче алачыгы, 5 сыраханә, казна шәраб, 5 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3133 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чишмә волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1984 нең 3 июленнән — Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1782 дә — 226 ир-ат, 1859 да — 1475, 1897 дә — 1956, 1908 дә — 2374, 1920 дә — 2913, 1926 да — 2082, 1938 дә — 2088, 1949 да — 1269, 1958 дә — 981, 1970 тә — 1201, 1979 да — 961, 1989 да — 672, 2002 дә — 816 кеше.

**ЯЛАУ́Р** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 40 *км* төньяк-көнбатыштарак Тимерлек елгасы буенда. 2010 елда 436 кеше (чуашлар) яши. Халыкның төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан мәгълүм.

Рев-циягә кадәрге чыганакларда Микушкино исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерче алачыгы, мичкә ясау, балта эше, күн аяк киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), 2 тимерче алачыгы, җил тегермәне, су тегермәне һәм атлы ярма яргыч, 3 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1660 дис. тәшкил итә. 1920 дән Казан губернасының Чистай өязе Иске Максимкино волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән — Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 111 ир-ат; 1859 да — 463, 1897 дә — 838, 1908 дә — 968, 1920 дә — 1337, 1926 да — 964, 1938 дә — 1110, 1949 да — 1010, 1958 дә — 1048, 1970 тә — 3223, 1979 да — 919, 1989 да — 582, 2002 дә — 491 кеше.

**ЯЛГА́Н ЧАЯННА́Р** (Pseudoscorpiones яки Chelonethi), үрмәкүчсыманнар отряды. Якынча 2 мең төре билгеле, Россиядә — якынча 60, Татарстанда Я.ч. фаунасы аз өйрәнелгән. Кечкенә буынтыгаяклы бөҗәкләр, тышкы кыяфәте б-н чаяннарга (исеме шуннан) охшаш, әмма корсаклары киң һәм арткы койрык өлеше юк. Гәүдәсенең озынлыгы 1–7 *мм*, башкүкрәге хитин тышча б-н капланган, алгы очында күзләре һәм авыз органнары — бер пар кыскычсыман хелицерлар һәм корбанын тоту өчен хезмәт итүче, агулы бизле (кайбер төрләрендә) зур кыскычлы бер пар аяк-казналыклар урнашкан. Я.ч. аерым җенесләләр, ана зат аталанган күкәйне гәүдәсенең корсак астындагы оя камерасында саклый. Бөтен җирдә, башлыча, тропикларда һәм субтропикларда таралганнар. Яшерен яшәү рәвеше алып баралар, урман түшәлмәсендә, кабыклар, ташлар астында, кырмыска ояларында, хайван өннәрендә һәм ояларында, терлек биналарында, ш.у. китапханәләрдә һәм кеше торакларында яши. Кечкенә талпаннар, бөҗәкләр, балавыз көясе личинкалары б-н туена. Китап ялган чаяны (Chelifer cancroides) йортларда еш күренә.

**«ЯЛКЫ́Н»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Саратов губерна ком-ты, аннары ВКП(б)ның Сталинград край ком-ты һәм край башкарма ком-ты, ВКП(б)ның Әстерхан шәһәр ком-ты, Эшче, крәстиян, кызылармияче депутатларның шәһәр советы һәм профсоюзларның шәһәр советы органы. 1918 елның 1октябреннән 1932 гә кадәр Саратов шәһәрендә, 1932–35 тә Әстерханда татар телендә нәшер ителә, барысы 1200 саны чыга. Исеме үзгәрә: 1920 нең 11 февраленә кадәр — «Ышаныч», 1920–23 һәм 1932–35 тә — «Я.», 1924–31 дә — «Идел буе». Мөхәррирләре — Д.Йосыпов, Г.Әюпов, З.Сүнчәләй, Г.Нурмөхәммәтов, Х.Хисаметдинов, С.Давыдов, М.Фәтхуллин һ.б. Актив авторлары арасында — И.Таһиров, Х.Кәримов, В.Гали, Г.Гафуров, Г.Бикмуллин, К.Ханбиков, Х.Исхаков һ.б. Газета дөнья рев-циясе идеяләрен пропагандалый, иҗтимагый-сәяси проблемаларга зур игътибар бирә. «Я.»да төбәкнең мөселман советлары корылтайлары эше чагылдырыла, бөтенроссия һәм җирле хакимият органнары карарлары басыла. Газета битләрендә бишьеллык планнар үтәлешенә, индустрияләштерү, күмәкләштерү, кооперация хәрәкәтенә зур урын бирелә; татарларның мәдәни тормышы, мәгариф үсеше, татар укытучылары, мәдәният эшлекләләре съездлары эше яктыртыла; татар балалар бакчалары һәм мәктәпләренең, техникумнарының тиешенчә финансланмавы б-н бәйле борчулары белдерелә. 1926 да аерым мәкаләләр татар театры оешуның 20 еллыгына, Әстерхан татар театры эшчәнлегенә багышлана, театр рецензияләре басыла.

**«ЯЛКЫ́Н»**, айлык әдәби-нәфис, рәсемле балалар журналы. 1924 елның мартыннан Мәскәүдә, 1951 дән Казанда татар телендә нәшер ителә. Исеме үзгәрә: 1924–28 дә — *«Кечкенә иптәшләр»*, 1928–32дә — *«Октябрь баласы»*, 1933–41 дә — *«Пионер каләме»* (1941–50 дә чыкмый), 1951 дән — «Пионер», 1957 дән — «Я.» Журналны оештыручы — шагыйрь М.*Җәлил*. Мөхәррирләре — Х.Курмаев, М.Җәлил, Р.Хәмиди, Л.*Гыйльми*, Г.Хәбибуллин,




«Ялкын» журналы.

А.*Әхмәт*, Л.*Ихсанова*, Г.*Мөхәммәтшин*, Р.*Хафизова*, Р.*Туфитуллова*, Ж.*Дәрзаманов*, Э.*Закирова*, Й.Миңнуллина, И.Фазлуллин (2017 дән). Авторлары арасында — Г.Кутуй, А.Мохтаров, Ш.Усманов, М.Крымов, А.Алиш, Ж.Тәрҗеманов, Ш.Мөдәррис, М.Әгъләмов, Р.Зәйдулла, Л.Лерон, С.Гаффарова, Л.Янсуар һ.б. Журнал 10–16 яшьлек яшүсмерләргә юнәлтелә, игътибар үзәгендә — аларның тормышы, мәнфәгатьләре һәм проблемалары. Дидактик характердагы материаллар, әдәби әсәрләр басыла. Мәдәният һәм сәнгать турындагы мәкаләләр б-н «Я.» үсеп килүче буында сәнгати зәвык тәрбияләргә омтыла. Яшьләрнең кумирлары турындагы мәкаләләргә, татар мәдәниятенең күренекле эшлекләләре б-н әңгәмәләргә зур урын бирелә. ТР Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» (1999, 2005), ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. бүләкләренә (2006) лаек була. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Хафизова Р. Уртак эшебез // Совет мәктәбе. 1984. № 5; Мөслимова Ф. «Ялкын» — дуслык учагы // Татарстан. 1999. № 5; Галиева А. Сиксәндә дә ул бала // Казан утлары. 2004. № 3; Фаткуллина Р. «Ялкын» и детская литература // Детская литература. 1979. № 9.

**ЯЛКЫ́Н** авылы, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 41 *км* көньяк-көнбатыштарак, Актай елгасы буенда. 2010 елда 287 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 69 %) яши. Халыкның төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Китапханә. 1929 да нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Спас кантоны Левашёво волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1926 да — 51, 1938 дә — 84, 1949 да — 195, 1958 дә — 132, 1970 тә — 242, 1979 да — 378, 1989 да — 334, 2002 дә — 311 кеше.

**ЯЛМАЧА́**, камчау (Scabiosa), төкчәләләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, ярымкуакчыклар ыругы. 100 гә якын төре билгеле, Евразия, Африкада, башлыча Урта диңгез буенда таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Исет Я.сы (S. isetensis) Көньяк-көнчыгыш Кама арьягында очрый. Ташлы тау битләрендә үсә. 20–40 *см* биеклектәге ярымкуакчык. Тамыры калын, агаччыл, күпбашчалы. Сабагы туры, кыска бөдрә төкчәле. Өске сабак яфраклары каурыйсыман, аскылары икешәр каурыйсыман. Сары Я. (S. ochroleuca) ара-тирә Идел алдында һәм Кама арьягында очрый. Болыннарда, куаклар арасында үсә. 30–90 *см* биеклектәге, үзәк тамырлы, күпьеллык үләнчел үсемлек. Сабагы ботаклы. Сабак яфраклары каурыйсыман-киселмә, тамыр янындагылар һәм аскылары — эллипссыман. Я.ның чәчәкләре аксыл-сары төстә, озын чәчәк сапларындагы башча чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — орлыкча. Июнь-сентябрьдә чәчәк аталар. Җимешләре август-сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Баллы һәм декоратив үсемлекләр. Сары Я.ның җир өсте өлешләрендә сапонин, алкалоид, органик к-талар бар. Халык медицинасында үләненең төнәтмәсе ашказаны авыртулары вакытында, тәнгә ябу өчен файдаланыла. Исет Я.сы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**«ЯЛТ-ЙО́ЛТ»**, сатирик, юмористик рәсемле журнал. *«Яшен»* ж-лы дәвамчысы. 1910 елның 15 маеннан 1918 нең июненә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә. Айга 2 тапкыр басыла, барысы 123 саны чыга. Мөхәррире — Ә.Урманчиев. Җаваплы сәркәтибе — Г.Тукай, ул баш мөхәррир вазифасын да башкара. Журналда Тукайның 50 гә якын шигыре, 1910–15 тә язылган сатирик, прозаик һәм публицистик әсәрләре (фельетоннар, памфлетлар, хикәяләр, эпиграммалар, пародияләр) басыла. 1913 нең 10 апрелендә дөнья күргән саны, ш.у. 1914–16 ның апрель савнары тулысынча Тукай истәлегенә багышлана. Ф.Әмирхан «Ташмөхәммәд», «Т.Д.», «Җамҗаметдинов» тәхәллүсе б-н сатирик әсәрләрен чыгара. Әдәби кыйммәте аз булган әдәбиятка рецензияләрен ул «Имгәк» тәхәллүсе б-н, сәяси сатирага — «Әүлия уллахтан бер залим», дини «Дин вә мәгыйшәт» ж-лы язмаларына карата булганнарын «Хәл-

фә» тәхәллүсләре б-н бастыра. «Я.-й.»та Г.Камалның шигырьләре, фельетон һәм пародияләре, ш.и. аның «Яшенче» тәхәллүсе б-н график әсәрләре дөнья күрә. Журнал б-н Ш.Әхмәдиев, Ф.Бакир, И.Биккулов (тәхәллүсе «Акмали»), С.Галимов («Дәҗҗалов»), Н.Думави («Өй анасы»), Х.Искәндәров («Астыртын»), Х.Исхакый, Һ.Килдебәков, Г.Коләхмәтов, Т.Мирзалиев («Тимер Калтай»), Ш.Мостаев («Ш.М»), С.Рахманколый, С.Сүнчәләй,



«Ялт-Йолт» журналы.

М.Укмаси һ.б. хезмәттәшлек итә. Г.Ибраһимовның М.Солтановның мөфти вазифасында булуына 25 ел тулуга багышланган «Буш юбилей» язмасы зур яңгыраш таба. Тукай б-н Камал журналга эшкә Ш.Гайфи, С.Яхшыбаев кебек рәссамнарны җәлеп итә. «Я.-й.» Идел-Урал төбәге татарларында зур популярлык казана, башкорт, казакъ, үзбәк, әзәрбайҗаннар арасында тарала.

*Әд.:* Гимадиев У.И. Сила сатирического слова. К., 1987.

**ЯЛТА́У** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 40 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасыннан 2 *км* читтә. 2010 елда 122 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1928 дә Иске Иштирәк авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Шөгер волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1938 дә — 397, 1949 да — 391, 1958 дә — 379, 1970 тә — 242, 1979 да — 244, 1989 да — 123, 2002 дә — 130 кеше.

**ЯЛТЫРАВЫ́К ЭНӘ́ КАРАГЫ́** (Calopteryx splendens), энә караклары семьялыгыннан. Гәүдәсенең озынлыгы 5 *см* га кадәр, ата затлар металлсыман-зәңгәр, ана затлар алтынсыман-яшел төстә. Канат җәеме 6 *см* га кадәр: ата затларның канатлары төбе һәм очы төссез, уртасы киң зәңгәр бәйләвечле; ана затларның — төссез диярлек, металлсыман-яшел сеңерле. Татарстанның бөтен терр-ясендә таралган. Елга һәм инеш буйларында тереклек итә, судан ерак китми. Әкрен җилпенеп оча. Ерткыч, бөҗәкләр б-н туена. Личинкалары суда үсә.

**ЯЛТЫРАКБА́Ш**, куян йоны (Luzula), кугачалар семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 80 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарда, ш.у. тропикларның тауларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар: күп чәчәкле Я. (L. Multiflora), аксыл Я. (L. pallidula), төкле Я. (L. pilosa). Ара-тирә барлык районнарда да очрый. Урманнарда, болыннарда, юл буйларында үсә. 5–35 *см* биеклектәге үсемлек, кәс барлыкка китерә. Сабагы туры. Яфраклары яссы кыяк; сабактагылары тамыр янындагыларга караганда кечерәк, берле яки күчләрдә, читләре ак төкчәле. Чәчәкләре кечкенә, көрән яки яшькелт төстә, чатыр яки башча чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — бер оялы өч орлыклы тартмачык. Орлыгы өстәмә үсентеле. Май-июньдә чәчәк ата. Җимешләре июнь-июльдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (тамырчалардан) үрчи. Терлек азыгы. Төкле Я.ны декоратив үсемлек буларак үстерәләр.

**ЯЛУ́ТОР РАЙОНЫ́**, *Төмән өлкәсенең* көнбатыш өлешендә урнашкан. 1923 елда оештырыла. Мәйданы — 2847 *км*². Үзәге — Ялуторовск шәһәре (Төмән шәһәреннән 75 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 14594 кеше (2017). Татарлар саны — 2010 елгы халык исәбе буенча, 3799 кеше яши. Алар, тупланып, Аслана (Кышавыл), Яңа Атьял, Рауды, Сәел (Татарский Сингуль), Калмаклар (Абазбакеево), Кактамак (Красный Яр), Көлек, Мәңгәр, Күлавыл (Озёрная), Бумаер (Осинова), Исәт (Яр) авылларында яшиләр; өлкә карамагындагы Ялуторовск шәһәрендә 2,5 меңләп татар исәпләнә. Я.р. терр-ясендә Себер (Төмән) татарлары күптәннән яшиләр. Ялуторовск шәһәре 1639 да борынгы Яулы Тура («сугышчан шәһәр» яки «сугышлар шәһәре») татар шәһәрлеге урынындагы Ялутор зиндан (соңрак бистәсе) буларак нигезләнә. 19 йөз ахырында Ялутор өязендә 5 меңләп кешесе булган 18 татар авылы исәпләнә. Я.р. милли-мәдәни автономиясе (1998 дән), «Таң» Себер татарлары милли-мәдәни автономиясе (2009 дан), Ялуторовск шәһәренең Милли-мәдәни һәм һөнәри үзәге каршында татар мәдәнияте бүлеге, Аслана авылында район татар мәдәнияте үзәге (1977 дән); 5 татар мәктәбе (Аслана, Яңа Атьял, Сәел, Калмаклар, Исәт авыллары), «Тамаша» халык фольклор коллективы (Аслана а.) эшли. 2012 дә Ялуторовскида татар балалары өчен җәйге лагерь лар оештырыла. «Татар радиосы-Төмән» радиостанциясе тапшырулары трансляцияләнә (2008 дән). 10 мәчет, ш.и. 5 се — даими (Ялуторовскида, Аслана, Яңа Атьял, Калмаклар, Бумаер авылларында), 5 се дини бәйрәмнәрдә эшли. Я.р.нда (Бумаер а.) Сов. Союзы Герое Т.К.*Ишмөхәммәдов* туган.

**Я́ЛЬЧИК РАЙОНЫ́**, *Чуаш Республикасының* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1927 елның 5 сентябрендә оештырыла. Мәйданы — 567,2 *км*². Үзәге — Яльчик авылы (Чабаксардан 150 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 17329 кеше (2017), ш.и. 332 татар (2010). Татарлар Сориле (Ишмурзино-Суринск, 1670 тән билгеле, 2010 да — 198 кеше) һәм Яңа Бикшек (1924 тә нигез салына, 45 кеше), Яльчик (87 кеше) авылларында яшиләр. Кошки-Куликеево авылы башлангыч мәктәбендә укыту татар телендә бара, югары сыйныфларда татар теле фән буларак өйрәнелә. Сориле авылы мәдәният йорты каршында «Татар халкының гореф-гадәтләре» түгәрәге эшли. 2008 дә «Китап аша — халыклар бердәмлегенә» 6 нчы Төбәкара милли китап фестивале чикләрендә «Идел буе халыкларының дус гаиләсендә» исеме б-н Татар китабы көне, 2013 тә «Бердәмлек — мәдәният аша» милли мәдәниятләр фестивале чикләрендә «Татарстан-Чуашстан: без бердәм Россия» Татар мәдәнияте көне үткәрелә. 2 мәчет, Яңа Бикшек авылында җирле дини оешма эшли. Химик, СССР ФА академигы Х.М.*Миначёвның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Я.р. б-н бәйле.

**«ЯЛЧЫ́»**, газета, к. *«Авыл хуҗалыгы эшчесе»*.

**ЯЛЧЫГО́Л** Таҗетдин (1763, хәзер Азнакай р-ны Чалпы а. – 26.6.1838, хәзер Зәй р-ны Имәнлебаш а.), татарлар арасында *абызлар (абызагайлар) хәрәкәтен* башлап җибәрүчеләрнең һәм аның җитәкчеләренең берсе, тарихчы, язучы, педагог. «Тәварихы Болгарийә» (1805) китабында Я. әтисе б-н хаҗга баруы, әтисе аны Төркиянең Диярбәкер шәһәрендә калдырып китүе, анда 14 ел дәвамында мәдрәсәдә укуы, аннан соң Истанбул шәһәренә барып, икенче хаҗдан кайтып килүче әтисе б-н очрашуы хакында яза. Ике елдан соң туган якларына кайтып барганда, алар Әстерханда, Мәскәүдә, Түбән Новгородта һәм Казанда озакка тукталалар. 1785 елда Я.ның әтисе Кече Сон авылы тирәсендә (хәзер Мамадыш р-ны) авырып үлә. Үләр алдыннан улына шушы урыннарга якынрак яшәргә, елга ике тапкыр үзенең каберен зыярәт кылырга васыять итеп калдыра. 1792–99 да Татар Ерыклысы (хәзер Түбән Кама р-ның Каенлы а.), 1799–1824 тә Красная Кадка (хәзер Түбән Кама р-ны) авылында яши. Фәнни трактатлар язу б-н шөгыльләнә, дин гыйлемен укыта, җәй көннәрендә күрше авылларга барып, авыруларны дәвалый.

Я.ның иң күләмле әсәре — «Рисалә-и Газизә» (1795; 2001 дә нәшер ителә). Әлеге әсәр *Аллаһияр Суфиның* «Сөбәт әл-гаҗизин» (18 йөз ахыры) китабына язылган шәрехтән гыйбарәт. Китап Я.ның кызы үтенече б-н языла һәм аның исеме б-н атала. Китапта Аллаһияр Суфиның һәм аның остазларының тәрҗемәи хәлләре, танылган суфи шәехләрнең тормышыннан ярым мифик гыйбрәтле хикәяләр, әхлакый-дидактик һәм фантастик характердагы сюжетлар китерелгән ике юллык шигырь-шәрехләүләрдән торган «Сөбәт әл-гаҗизин»нең тулы тексты урнаштырылган. Әлеге әсәр татарлар арасында киң тарала, мәктәп һәм мәдрәсәләрдә дәреслек итеп файдаланыла. Кулъязма вариантта билгеле, 1847 дән берничә тапкыр кабат басыла.

Я.ның «Сидрат әл-мөнтаһа», «Тәварихы Болгарийә» һ.б. әсәрләрендә тарих, әдәбият, халык медицинасы, мөселман хокукы, тәрбия мәсьәләләре карала.

*Әд.:* Гарифуллин Д. Чырагы нур сибә бүген дә (Т.Ялчыголның тууына 240 ел) // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2008. № 2; XVII йөз татар әдәбияты: Проза. К., 2012; Галяутдинов И.Г. «Тарих нама-и булгар» Таджетдина Ялсыгулова. Уфа, 1998; Гайнетдинов М.В. Т.Ялчыгул //

История татарской литературы средневековья (VIII–XVIII вв.). К., 2007.

**«ЯЛЧЫЛА́Р САГЫШЫ́»**, хокуксыз батракларның авыр язмышы турында татар халык лирик җыры. Аларның тормышын тасвирлау табигатьне поэтик тасвирлау б-н үрелеп бара. Һәр строфа кабатлана торган юллардан башланып китә. Әлеге алым җырның тәэсирлелеген көчәйтә. Беренче тапкыр «Я.с.» җыры 1926 елда Новосибирск өлкәсенең Бараба р-ны Тармакүл авылында Х.Рәхмәтуллин тарафыннан язып алына.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988. *Ф.И.Урманчеев.*

**ЯМА́Л-НЕ́НЕЦ АВТОНО́МИЯЛЕ О́КРУГЫ**, Төмән өлкәсендә, Көнбатыш Себер тигезлегеннән төньяктарак урнашкан. Ерак Төньяк районнарга керә. 1930 елда Урал өлкәсе, соңрак Обь-Иртыш һәм Омск, 1944 тән Төмән өлкәләре составындагы Ямал (Ненец) милли округы буларак оештырыла. 1977 дән — автономияле округ. Мәйданы — 769,2 мең *км*². Үзәге — Салехард шәһәре (Мәскәүдән 1935 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Төмән шәһәреннән 1047 *км* ераклыкта). Халкы — 534104 кеше (2016). 28509 татар яши (2010). Алар Ноябрьск (2010 да — 7416 кеше), Яңа Уренгой (5206), Салехард (3647), Муравленко (3118), Губкинский (1645), Лабытнанги (739) шәһәрләрендә һәм Надым (2952), Пур (2213), Тазовский (505), Ямал (443), Приуралье (298), Красноселькуп (216), Шурышкары (129) р-ннарында яшиләр. Җирле татар җәмгыяте миграция, ш.и. 1930 еллар башындагы күмәкләштерү сәясәте, 1940–50 һәм 1970 елларда төбәкне сәнәгый үзләштерү чорындагы көчләп күчерүләр нәтиҗәсендә оештырыла. Хәзерге вакытта 13 үзешчән татар иҗат коллективы: «Дуслык» татар җыры ансамбле, «Йолдыз» татар җыры вокаль квартеты (Салехард ш.), «Ләйсән» вокаль ансамбле һәм «Очрашу кичәсе» татар мәдәни клубы (Лабытнанги ш.); «Бәхет» татар-башкорт җыры ансамбле (Яңа Уренгой ш.), «Бәйрәм» вокаль ансамбле (Ноябрьск ш.), «Дуслык» вокаль ансамбле һәм «Мирас» татар-башкорт мәдәни клубы (Муравленко ш.); «Әбиләр-гөлләр» («Аби гуль») фольклор ансамбле һәм «Якташлар» клубы (Губкинский ш.); «Дуслык»татар-башкорт милли клубы (Надым р-ны); «Агыйдел» татар-башкорт биюләре хореографик ансамбле һәм «Умырзая» һәвәскәр берләшмәсе (Пур р-ны), 6 иҗтимагый оешма: төрки халыкларның «Васыять» иҗтимагый оешмасы (2002 дән, Надым шәһәрендә һәм Надым р-нында), «Чулман» төбәк татар-башкорт иҗат берләшмәсе (2011 дән, Яңа Уренгой ш.), җирле: «Умырзая» татар-башкорт иҗтимагый оешмасы (2002 дән, Муравленко ш.), «Нур» татар милли-мәдәни автономиясе (2009 дан, Ноябрьск ш.), татарларның «Ватан» милли-мәдәни автономиясе (2012 дән, Салехард ш.), «Дуслык» татар милли-мәдәни автономиясе (2015 тән, Ноябрьск ш.) эшли. 1992–2012 дә «Ямал-Регион» дәүләт телерадиотапшырулар комитеты татар телендә «Туган нурлар» тапшыруын трансляцияли. 2011 дә Я.-Н.а.о. б-н ТР арасында Сәүдә-икътисад, фән-техника, социаль һәм мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүгә кул куела. Салехардта ел саен Сабан туе уздырыла. 2000 нән мөселман җәмгыятьләренең эшчәнлеге кабат торгызыла. Хәзер округ терр-ясендә 7 мәчет эшли. Язучы М.К.Абдулинның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Я.-Н.а.о. б-н бәйле.

**ЯМА́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Бөгелмә Зәе елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 17,4 *км*. Бассейнының мәйданы 100,4 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага. Елга башы Әлмәт р-ны Акчишмә авылының көнбатыш чигендә, тамагы Азнакай р-ны Микулин авылыннан 2 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 280 *м*, тамагыныкы — 141 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 50%. Я.ның 0,7 дән 4 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*². Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 81 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 49 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,112 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Я. бассейнында *Владимировка сөзәклеге* табигать саклаулыгы урнашкан.

**ЯМА́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кичү елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 13,6 *км*. Бассейнының мәйданы 58,3 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Әлмәт р-нында ага. Елга башы «Уратма дачасы» урман массивында, тамагы Аргы Ямаш авылының төньяк-көнбатыш чигендә. Елга башының абс. биеклеге 205 *м*, тамагыныкы — 74 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 65%. Я.ның 1,4 тән 4,1 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*². Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 116 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 68 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,096 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЯМА́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 11 *км*. Бассейнының мәйданы 42 *м*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Әлмәт р-нында ага. Елга башы Берёзовка авылыннан 5 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Аргы Ямаш авылының көньяк-көнчыгыш читендә. Елга башының абс. биеклеге 250 *м*, тамагыныкы — 82 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Я.ның 0,4 тән 2,8 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 82 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,032 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**ЯМА́Ш**, к. *Аргы Ямаш*, Әлмәт р-ны.

**ЯМА́Ш** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 30 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чошы елгасы буенда. 2010 елда 485 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 нән рус чыганакларында Починок на пустоши Кибекеевской исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кибәк, Емаш исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, дуга ясау б-н шөгыльләнә. 18 йөзнең уртасында авыл халкының бер өлеше көчләп чукындырыла, 1866 да ислам диненә кире кайта. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 2 тегермән, 4 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1906 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 619, 1897 дә — 974, 1908 дә — 1311, 1920 дә — 1229, 1926 да — 1200, 1938 дә — 1130, 1949 да — 844, 1958 дә — 745, 1970 тә — 908, 1989 да — 639, 2002 дә — 586 кеше.

**ЯМА́Ш** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 26 *км* төньяктарак, Шыя елгасыннан (Вятканың уң кушылдыгы) 1км читтә. 2010 елда 237 кеше (татарлар) яши. Халыкның төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз уртасында Иске Горелый Ельник авылыннан (хәзерге Мамадыш р-ны Вахитов а.) күченеп килүчеләр тарафыннан нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новый Горелый Ельник, Новопоселённый Горелый Ельник, Студёный Ключ исемнәре б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз

башында Я.та мәчет, вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 585,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 10 ир-ат; 1859 да — 211, 1897 дә — 422, 1908 дә — 507, 1920 дә — 589, 1949 да — 381, 1958 дә — 360, 1970 тә — 430, 1979 да — 364, 1989 да — 269, 2002 дә — 271 кеше.

**ЯМА́Ш ИГӘНӘ́Й** (тәхәллүсе, чын исеме һәм фамилиясе Малов Ананий Нестерович) (10.1.1938, Сарман р-ны Ләке а. — 1.1.1997, Чаллы ш., туган авылында җирләнә), шагыйрь. Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1960 елдан Сарман р-ны мәктәпләрендә укыта, 1965–78 дә Баулы, Мамадыш район газеталарында эшли. 1978 дән Чаллы шәһәрендә: «Камэнергострой» ЖБнең «Кама таңнары» г-тасында хәбәрче (1980 гә кадәр), 1986 дан ТАССР Язучылар берлегенең Чаллы бүлегендә җаваплы сәркәтип, 1988 дән «Чулман-Идел» г-тасы редакциясендә хатлар бүлеге мөдире, 1991 дән «*Аргамак*» ж-лы мөхәррире. «Сәфәр чыгам» (1981), «Хәзинәләр иле» (1984), «Игелекле төбәк» (1987) шигырь җыентыкларына тормыш, үткән юл турында уйланулар, нечкә лиризм хас. Балалар өчен «Йолдыз булып ян» (1983), «Мин әтигә охшаган» (1989) шигырь җыентыклары һәм Кырым татарларына багышланган «Бәддога» (Чаллы, 1994) публицистик мәкаләләр китабы авторы. «*Керәшен сүзе — Слово кряшен*» г-тасын оештыручы һәм беренче баш мөхәррире (1992–97). Ләке авылындагы урта мәктәп аның исемен йөртә, шунда ук шагыйрьгә багышланган музей ачылган.

*Әд.:* Б ә ш ә р Р. Сабый җанлы шагыйрь // Аргамак. 1998. № 1; Ф ә й з у л л и н Р. Салмак, әмма саллы // Сайланма әсәрләр. К., 2005. Т. 5.

**ЯМА́Ш РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1944 елның 19 февралендә оештырыла. Үзәге — Ямаш авылы. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының — Чистай, Уфа губернасының Минзәлә өязенә керә, 1920 дән ТАССРның — Чистай һәм Минзәлә, 1921 дән Чистай һәм Чаллы кантонында, 1930 дан Яңа Чишмә һәм Акташ р-ннарында. 1948 дә Я.р. 23 авыл советын һәм 63 торак пунктны берләштерә. 1956 да районның мәйданы 801,5 *км*² була, 13 авыл советы һәм 43 торак пункт исәпләнә. 1956 ның 7 декабрендә Я.р. таркатыла, терр-ясе Акташ һәм Яңа Чишмә р-ннарына бирелә.

**ЯМА́ШЕВ** Илгиз Гариф улы (15.1.1937, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (1993), проф. (1994), ТАССРның атказ. табибе (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Әтнә район хастаханәсе табиб-стоматологы булып эшли, 1962 елдан ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка стомат. поликлиникасы хирург-стоматологы. 1976 дан — терапевтик стомат., 1979 дан — хирургик стомат., 1988 дән казналык-бит хирургиясе кафедраларында, 2007 дән Казан мед. академиясенең (ГИДУВ) казналык-бит каф. профессоры. Хезмәтләре телдәге авырулар һәм җәрәхәтләр, казналык сөякләре сыну очракларын дәвалау ысулларына карый. Пётр исемендәге фән һәм сәнгать академиясе хакыйкый әгъзасы (С.-Петербург, 2005). Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы, 2 РФ патенты бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Хирургические заболевания и повреждения языка. Л.,1984; Новые варианты шин для лечения переломов нижней челюсти. К., 2007 (автордаш); Роль языка в формировании адаптационных механизмов при имплантации // Рос. стомат. журн. 2010. № 6 (автордаш); Причины развития макроглоссии и её влияние на зубочелюстную систему // Здравоохранение Чувашии. 2012. № 1(автордаш).

*Әд.:* Профессор И.Г.Ямашев (к 70-летию со дня рождения) // Стоматология. 2007. № 4.

**ЯМА́ШЕВ** Хөсәен Минһаҗетдин улы (6.1.1882, Казан — 13.3.1912, шунда ук), революцион хәрәкәт эшлеклесе. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең җиде сыйныфын (1897), Казан татар укытучылар мәктәбен (1902) тәмамлый. Мәктәптә Я. демократик карашлы татар яшьләреннән торган түгәрәк оештыра. 1903 елдан РСДРПның Казан ком-ты әгъзасы. Бертуган Алафузовлар з-дында, Казанның башка пр-тиеләрендә (1903), Казан татар укытучылар мәктәбендә (1904) марксистик түгәрәкләр оештыра. Татар теленә социал-демократик эчтәлекле листовкаларны («Ко всем рабочим города Казани», «К обществу» һ.б.) тәрҗемә итә. 1905–07 елгы Россия рев-циясендә катнаша, РСДРПның Казан ком-ты каршындагы татар төркемен җитәкли. Я. җитәкчелегендә большевиклар ком-тының китаплар һәм листовкалар бастыру эше җайга салына. Яшерен фатирларда һәм үзенең өендә 6 гектограф урнаштыра; татар телендә сәяси листовкалар, брошюралар нәшер итә («Үрмәкүчләр һәм чебеннәр» — «Пауки и мухи», «Беренче адым» — «Первый шаг», «Төпчек патша» — «Царь-последыш», «Сыйныфка каршы сыйныф» — «Класс против класса» һ.б.). 1905 тә РСДРПның Казан ком-ты тар-мар ителгәннән соң, Я. Уфага күчеп китә, РСДРПның Уфа ком-тында татар-башкорт төркемен җитәкли. 1907 нең гыйнварында Оренбург шәһәрендә РСДРПның Уральск һәм Уфа ком-тлары ярдәме б-н татар социал-демократларының беренче легаль «Урал» г-тасын нәшер итүгә ирешә. 1907 дә хөкүмәткә каршы материаллар бастырганы өчен, Я.ка каршы тикшерү процессы башлана, ул 1909 га кадәр сузыла. 1907 нең җәендә Казанга кайта, революцион эшчәнлеген дәвам иттерә. Шул ук елда, ирекле тыңлаучы булып, Казан ун-тының юридик ф-тына керә (бераздан авыруы сәбәпле укуны ташлый). 1911 дә экстерн тәртибендә Казандагы Беренче ир балалар гимназиясен тәмамлый, Казан ун-тына кабат кереп, анда революцион түгәрәк оештыра. Г.Тукай, Ш.Мөхәммәдов, Г.Камал, М.Гафури һ.б. татар демократик зыялыларының иҗатына зур йогынты ясый. Г.Тукай Я. үлеменә багышланган шигырендә болай яза: «Ул көрәште һәм явыз эшкә җәза бирде көләп, Үткен акълы шул көрәшкә пакь көмештән юл булып». Казанның бер проспекты Я. исемен йөртә.



Х.М.Ямашев.



Х.М.Ямашев татар яшьләр әдәби түгәрәге әгъзалары арасында (уңнан икенче).

*Әд.:* Хусаин Ямашев. К., 1972; Х а с а н о в Х.Х. Революционер-интернационалист: Жизнь и деятельность Хусаина Ямашева. К., 1981.

*Л.М.Айнутдинова.*

**ЯМА́ШЕВ Х. ИСЕМЕНДӘГЕ́ РЕСПУ́БЛИКА БҮЛӘГЕ́**, к. *Татарстан Республикасының Журналистлар берлеге бүләкләре.*

**ЯМА́ШЕВ Х. ИСЕМЕНДӘГЕ́ ТАТА́Р КИТАПХАНӘСЕ́**, Оренбургта. 1906 елда Оренбург мөселман хәйрия җәмгыяте китапханәсе уку бүлмәсе буларак ачыла. 1920 дән милли азчылыкларның дәүләт Үзәк китапханәсе, 1928 дән Ямашев Х. исем., 1930 еллар ахырыннан хәзерге исемдә, 1980 нән Оренбург үзәкләштерелгән китапханә системасының 16 нчы ф-лы. 1910 да — 1510, 1917 гә якынча 13 мең том исәпләнә. Укучылар арасында — язучылар һәм шагыйрьләр Дәрдемәнд, М.Җәлил, Ш.Мөхәммәдов, Ф.Кәрим, Шамун Фидаи, артистлар Ф.Камалова, В.Фатыйхов. 1918–21 дә китапханә б-н Ш.Камал җитәкчелек итә. 1930 елларда ике тапкыр алфавитны алыштыру китап фондының кимүенә китерә (1939 да — 9143 исемдә). Алга таба фондлар тулыландырыла; 2009 га 50 меңнән артык китап исәпләнә. ш.и. 24 меңе — татар һәм башкорт телләрендә. Китапханә беренче елларыннан ук Оренбургның татар иҗтимагый тормышы һәм мәдәниятенең мөһим үзәге була. Анда музыка һәм драма түгәрәкләре эшли, күренекле кешеләр б-н очрашулар уза (авторларның бүләк язулы 200 дән артык китабы саклана), популяр лекцияләр, проф. һәм үзешчән татар рәссамнары күргәзмәләре, концертлар оештырыла. Хәзерге вакытта китапханә шәһәрнең татар халкы өчен мөһим мәдәни чаралар уздыру урыны булып тора. 1979–2008 дә китапханә мөдире — Н.М.Муксимова, 2008 дән — С.Х.Әхмәтҗанова.

*Әд.:* М у к с и м о в а Н.М. История библиотеки им. Х.Ямашева // Татары в Оренбургском крае: Материалы науч.-практ. конф. Оренбург, 1997; В и ш н я к о в а В. Татарская библиотека имени Х.Ямашева // Этнокультурная мозаика Оренбуржья. 2002. № 1.

**ЯМА́ШЕВА** (Таначева) Хәдичә Зариф кызы (1883, Казан губ. Чистай ш. — 29.9.1950, Красноярск крае Абан а.), җәмәгать эшлеклесе, табибә. Фельдшерлар уч-щесен тәмамлый (Казан, 1912; табиб-стоматолог дипломын алган беренче татар хатын-кызы). *Х.Ямашевның* хатыны. 1907 елда ире б-н бергә «Урал» г-тасын нәшер итә (Оренбург ш.), гыйнвар-апрель айларында аның рәсми мөхәррире була. 1912–37 дә Казан, Мәскәү, Урта Азиядә теш табибәсе булып эшли. Хатын-кызлар хәрәкәтендә актив катнаша: 1917 дә 1 нче Бөтенроссия мөселман хатын-кызлары корылтаеның делегаты һәм оештыру бюросы рәисе (1917, апрель), Мөселман хатын-кызлары җәмгыяте рәисе, Казан шәһәр думасы депутаты. Берничә тапкыр кулга алына. 1937 дә эмигрантлар б-н элемтә урнаштырганы һәм «пантюркистлар һәм милләтчеләр оешмасында катнашканы» өчен хөкем ителә. Икенче ире В.Ш.Таначев б-н бергә Ухтижим лагерена (Коми АССР) җибәрелә. 1945 тә ирекккә чыгарыла; 1949 да яңадан кулга алынып, Красноярск төбәгенә сөрелә. Үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* М и н һ а ж е в А. Зар-интизар булып // Социалистик Татарстан. 1989. 15 окт.; Б и к т и м и р о в а Т. Её звали «Джан апа» // Татарстан. 2002. № 6. *Ф.Г.Миңнеханов.*

**ЯМАШИРМӘ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 25 *км* көнчыгыштарак, Казансу елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 1126 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау; «Туран» ҖЧҖ татар милли һәм баш киемнәре тегү цехы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1565–67 елларда рус чыганакларында Емашурмская исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, курыс төшерү-мунчала ясау, олаучылык (Уфа губернасына товар ташу) б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.дә 2 мәчет (1834 һәм 1852 дә төзелә), мәдрәсә, земство мәктәбе, тимерче алачыгы, 2 мануфактура, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2509,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Чыпчык волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 300 ир-ат; 1859 да — 1599, 1897 дә — 1610, 1908 дә — 1793, 1920 дә — 1811, 1926 дә — 1796, 1938 дә — 1432, 1949 да — 1210, 1958 дә — 1138, 1970 тә — 1089, 1989 да — 1062, 2002 дә — 1096 кеше. Авыл зиратында 14 йөзгә караган кабер ташлары саклана. Я.дә ген.-майор Ф.К.*Зиннуров* туган.

**«ЯМАШНЕ́ФТЬ»**, нефть-газ чыгару идарәсе (НГДУ), «Татнефть» АҖнең структур берәмлеге. 1969 елда Татар гөмбәзе көньяк өлешенең көнбатыш сөзәклегендәге вак чыганакларны сынаулы файдалану, аларны сәнәгый эшкәртүгә кертү өчен нефть промыселы идарәсе буларак оештырыла. 1970 тән НГДУ. Эшләүчеләр саны — 2000 гә якын кеше (2017). Составына 5 нефть һәм газ чыгару цехы — катламнардагы басымны нормада тоту, нефть әзерләү һәм кудыру, җир астында скважиналарны ремонтлау цехлары, җитештерүгә хезмәт күрсәтү базасы керә. 9 нефть чыганагын — Шегурча, Ямаш, Сиренькино, Архангельск, Төги, Берёзовка, Ерсубайкино, Красная Горка, Екатериновка чыганакларын эшкәртә. 2012 гә бораулангн фонд 2748 скважина тәшкил итә, шуларның 2048 е файдаланыла. Эшкәртүдәге төп объектлар — Тула, Бобрики горизонтларының, девон утырмаларының терриген коллекторлары, ш.у. Турне катламының һәм Верея-Башкорт утырмаларының карбонатлы коллекторлары. Нефть чыгаруның макс. күрсәткеченә 1988 дә ирешелә (2,1 млн. *т*). 2012 нең 1 нче гыйнварына барлыгы 53 млн. *т* нефть чыгарыла. Нефть бирүчәнлекне арттыру өчен катламнарга басым ясауның чыгарылучы продукциянең сулылыгын 42 % күләмендә саклау мөмкинлеге биргән прогрессив алымнары — аз җитештерүчән, энергия саклаулы насос агрегатлары ярдәмендә адреслы һәм циклик рәвештә су кудыру кулланыла; ялгаулы полимер системалар файдаланыла; башта нефть промыселларның үзләрендә үк әзерләнә; нефть әзерләүнең резервуарлы технологиясе гамәлгә кертелә һ.б. НГДУ каршында шифаханә-профилакторий, спорт-сәламәтләндерү, тау чаңгысы комплекслары, ял базасы һ.б. эшли. «Я.» промыселлары җирлегендә мөстәкыйль «*Нурлатнефть*» (1979), «*Зәйнефть*» (1989) НГДУлары оештырыла. «Я.»нең күп кенә хезмәткәрләре хөкүмәт бүләкләренә лаек була: 1 кеше — ТР Дәүләт бүлеге лауреаты, 27 кешегә — ТРның атказ. нефтьчесе, 5 кешегә — РФ, ТРның атказ. геологы, 2 кешегә — РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре, 6 кешегә — РФ, ТРның атказ. транспорт хезмәткәре, 4 кешегә — РФ, ТРның атказ. энергетигы, 5 кешегә — РФ, ТРның атказ. төзүчесе, 1 кешегә — ТРның атказ. икътисадчысы, 2 кешегә — РФнең атказ. а.х. хезмәткәре, 1 кешегә — ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә; 2 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 4 кеше — Халыклар дуслыгы, 6 кеше — «Почёт билгесе», 1 кеше — 2 нче дәрәҗә Хезмәт даны, 7 кеше — 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары б-н бүләкләнә, 1 кеше «Россия меценаты» исеменә лаек була. НГДУ җитәкчеләре: Р.М.Шагалиев (1969–73), А.В.Мордвинцев (1973–84), И.Н.Чернышев (1984–85), В.В.Смыков (1985 дән).

**ЯМБА́Й**, к. *Индустриальный.*

**ЯМБАКТЫ́** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 46 *км* көнчыгыштарак, Сушка елгасының (Актайның сул кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 525 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Хәзерге Я. терр-ясендә халык Болгар чорыннан яши. 1626 да буш җирләр Зөя өязенең Каратай авылы морзасы йомышлы татар Ямбулат Бекшеевка бирелә. 1690 еллардан рәсми чыганакларда Я. буларак телгә алына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерче алачыгы, тегү, йон-тукыма ману, киндер сүсеннән җеп үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да 3 мәчет (1862,1884, 1904 тә төзелә), 8 тегермән, 1 ярма яргыч, 2 тимерче алачыгы, 10 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5174,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Никола-Пичкас волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 242 ир-ат; 1859 да — 1559, 1897 дә — 2389, 1908 дә — 2617, 1920 дә — 2462, 1926 да — 1333, 1938 дә — 1243, 1949 да — 956, 1958 дә — 948, 1970 тә — 1020, 1979 да — 838, 1989 да — 636, 2002 дә — 565 кеше. Авыл зиратында һәм аның тирә-ягында Болгар чоры (13–14 йөз) кабер ташлары саклана.

**ЯМБАКТЫ́** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 90 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Янбохтино, Янбухтина исемнәре б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да Троица чиркәве (1735–41 дә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход (1893 тә ачыла) һәм земство мәктәбе (1881), 1 су һәм 3 җил тегермәне, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2407,06 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930





1. «Ямашнефть» НГДУның административ бинасы; 2. Архангельскидагы нефть туплау станциясе.

ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 481 ир-ат; 1859 да — 1017, 1897 дә — 1237, 1908 дә — 1336, 1920 дә — 1375, 1926 да — 1081, 1938 дә — 999, 1949 да — 594, 1958 дә — 412, 1970 тә — 326, 1979 да — 247, 1989 да — 160, 2002 дә — 141 кеше.

**ЯМБУЛА́Т** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 23 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасы буенда. 2010 елда 155 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 55%, чуашлар — 44%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1667 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Шамардино, Хыркассы, Покровский исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, тегү, киез-киез итек, тимерче алачыгы, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да чиркәү, земство мәктәбе, фельдшерлык пункты, 15 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2328 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Тимбай волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 928, 1880 дә — 1156, 1897 дә — 1484, 1910 да — 1763, 1913 тә — 2045, 1920 дә — 1943, 1926 да — 1807, 1938 дә — 1055, 1949 да — 742, 1958 дә — 662, 1970 тә — 371, 1979 да — 302, 1989 да — 171, 2002 дә — 155 кеше.

**ЯМБУЛА́Т** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 6 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тәмте елгасы буенда. 2010 елда 167 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. Мәчет. 1678 дә рус чыганакларында Пустошь Янделетева, 18 йөздә Янбулатова исемнәре б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, өс-баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.та мәчет, мәдрәсә, су һәм җил тегермәне, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1258,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Олы Кибәхуҗа волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 60 ир-ат; 1859 да — 390, 1897 дә — 474, 1908 дә — 600, 1920 дә — 586, 1926 да — 412, 1949 да — 398, 1958 дә — 317, 1970 тә — 300, 1979 да — 175, 1989 да — 191, 2002 дә — 164 кеше.

**ЯМБУЛА́Т** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 38 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 108 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 61%, чуашлар — 37%) яши. Халыкның төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, бакчачылык. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1904 тә Ямбулат авылыннан (хәзерге Чуаш Респ-касы Урмай р-ны) күченүчеләр нигез сала. 20 йөз башында Я.та су тегермәне була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 500 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ивановка волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1908 дә — 173, 1920 дә — 161, 1938 дә — 170, 1949 да — 122, 1958 дә — 131, 1970 тә — 135, 1979 да — 151, 1989 да — 154, 2002 дә — 129 кеше. Я.та Сов. Союзы Герое С.В.*Коновалов* туган.

**ЯМБУЛА́Т-ПУСТЫ́Ш** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 32 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мишә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 26 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1680 нән билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, су тегермәне, вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 471,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 36 ир-ат; 1859 да — 143, 1897 дә — 246, 1908 дә — 226, 1920 дә — 221, 1926 да — 229, 1949 да — 167, 1958 дә — 141, 1970 тә — 149, 1979 да — 107, 1989 да — 64, 2002 дә — 43 кеше.

**ЯМБУ́РОВО** посёлогы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы, Балтач посёлогыннан 30 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кубыр елгасы буенда. 2010 елда даими яшәүчеләре юк. 18 йөздә нигез салына. 19 йөз ахырына кадәр Кызыл Чишмә исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балыкчылык, аучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 292 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Шода волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 17 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 162, 1884 тә — 98, 1926 да — 90, 1938 дә — 109, 1949 да — 71, 1958 дә — 38, 1970 тә — 40, 1979 да — 15, 1989 да — 3, 2002 дә — 1 (мари) кеше.

*Әд.:* Балтач энциклопедиясе. К., 2010. Т.2.

**Я́МБУШЕВ** Фәрит Җамалетдин улы (22.4.1940, Мордва АССРның Ләмбрә р-ны Ләмбрә а.), химик-органик, химия фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). 1967 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 2011 дән Казан ун-тында. Хезмәтләре мышьякорганик кушылмаларга багышлана. Я. этилфенилкарбоксиннар һәм аминофениларсиннарның кыен булдырылу кыен бер төркем энантиомерларын эшли. Аларның оптик активлыгы зурлыгы үзгәрүенә бензол боҗрасы алыштыргычларының йогынтысын билгели. Әйләнүнең беренчел билгесе саклану шартларында күкерт һәм оксидлагычлар тәэсире нәтиҗәсендә энантиомерлар әверелешен тикшерә. Мышьяклы һәм азотлы кушылмаларны: аминоарсиннарны, амидоарсонитларны, арсамидиннарны, диазадиарсетидиннарны һ.б.ны синтезлый; аларның төзелешен, электрофил һәм нуклеофил реагентлар тәэсире нәтиҗәсендәге әверелешләрен өйрәнә. Синтезланган кушылмалар арасында йөрәк эшчәнлеген стимуллаштыручы, гөмбәчеккә, бактерияләргә каршы, туберкулостатик активлыкка һәм микроорганизмнарга карата селективлыкка ия матдәләр булуы ачыклана. Алар нигезендә нәтиҗәле фунгицидлар, полимер стабилизаторлары һәм диңгез кораблары өчен кулланылган буяуларның сүүсем ябыштырмас компонентлары эшләнә. Я. җитәкчелегендә нефть эмульсияләрен җимерү технологиясе булдырыла («Татнефть» җитештерү берләшмәсендә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2008).

Хезм.: Стереохимия мышьякорганических соединений // Успехи химии. 1979. Т. 48, № 6 (автордаш); Мышьякорганические соединения с As=N связью. VIII. Реакционная способность (N,N-диарил)арсамидинов // Журн. общей химии. 1987. Т. 57, вып. 7 (автордаш); Синтез, свойства и димеризация диарилбром- и арилдибромарсазосоединений // Журн.общей химии. 1991. Т. 61, вып. 10 (автордаш).

*Әд.:* История Мордовии в лицах: Биогр. сб. Саранск, 1997. Кн. 2; Учёные Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. К., 2008.

**ЯМГУРЧЫ́ ХАН** (? — 1555), Әстерхан ханы (1546–47, 1550–54). Ак Күбек хан тәхеттән төшерелгәч, Я.х. хакимиятне үз кулына ала (1546). 1547 елда Кырым ханы Сәхибгәрәй Хаҗитарханны басып алып, Я.х.ны куып чыгара, ул хан тәхетен бары 1550 дә генә үзенә кайтара. 1554 тә рус гаскәре ярдәме б-н Хаҗитархан тәхетенә Дәрвиш Гали утыртыла, ул нугай морзасы Йосыф уллары б-н бергә Я.х.ны тәмам тар-мар итә.

*Әд.:* Зайцев И.В. Астраханское ханство. М., 2006.

**Я́МКИНО** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 51 *км* көньяк-көнбатыштарак, Актай елгасы буенда. 2010 елда 12 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1710 елларда нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да земство мәктәбе, 4 җил тегермәне, тимерче алачыгы, йон-тукыма ману, 4 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1303,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Левашёво волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 1 апреленнән —

Куйбышев, 1958 нең 16 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 664, 1897 дә — 967, 1908 дә — 1175, 1920 дә — 1018, 1926 да — 694, 1938 дә — 447, 1949 да — 263, 1958 дә — 273, 1970 тә — 174, 1979 да — 144, 1989 да — 65, 2002 дә — 33 кеше.

**ЯМОРЗА́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән көньяктарак, Әзи елгасы буенда. 2010 елда 207 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; нефть-газ чыгару. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сумала кайнату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да мәктәп, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 515 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Салагыш волостенда. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 1 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 74, 1887 дә — 188, 1905 тә — 223, 1920 дә — 407, 1926 да — 443, 1938 дә — 305, 1949 да — 506, 1958 дә — 395, 1970 тә — 326, 1989 да — 254, 2002 дә — 248 кеше.

**ЯМЧЫЛА́Р БИСТӘСЕ́**, 16 йөзнең 2 нче яртысында Казанның көньяк-көнбатышында, Болак елгасының сулъяк ярында барлыкка килгән торак пункт. Казанның 1565–68 еллардагы Писцовый кенәгәләрдә: «Болак артында патша галиҗәнапләре һәм бөек кенәзнең ныгытмасындагы Ямчылар бистәсе. Ямчылар бистәсендә барлыгы... 62 йорт», — дип искә алына. Я.б. шәһәрнең хәзерге Мәскәү урамы (элек Мәскәү тракты узган һәм ямчылар яшәгән) урнашкан өлешендә барлыкка килә. Я.б.ндә яшәүчеләрнең төп вазифасы ям тоту, ягъни почта, йөк ташу, «дәүләт кешеләрен» йөртү була. Шул ук Писцовый кенәгәләрдә язылганча, алар җан исәбе салымыннан азат ителәләр һәм бистәнең нинди дә булса эшләренә җәлеп ителмиләр. Я.б. терр-ясе тора-бара киңәя: аңа элекке Зур урам, Варфоломей, Триумфаль, Беренче Мокрый, Аркылы Владимир һәм Ямчылар урамнары керә. Аның көнбатыш тарафында Успение соборы урнаша, собордан башланган юл Казанның иске дамбасына һәм Казансу елгасы күперенә илтә. Көньяк ягыннан (хәзерге Таҗи Гыйззәт урамы) пристаньга таба дамба салына. 1729 елда Болак буйлап бистәнең чигенә кадәр сузылган шәһәр (бистә) дивары җимертелә һәм Я.б. шәһәр сызыгы эченә кертелә. Болакның уң ягындагы ирекле почталар станциясе 19 йөз ахырына кадәр эшли, анда уртача хакка атлар һәм экипаж алырга мөмкин була, ә елганың сул ягында почта атлары өчен печән һәм солы саклана. 1796 да 106 йорт исәпләнә.

*Әд.:* Б и к б у л а т о в Р., М у с т а ф и н Р. Казань и её слободы. К., 2001; М а н с у р о в а Ю. «Откуда есть пошла Адмиралтейская слобода...» // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2005. № 2.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ЯНА́ЕВ** Хәмзә Исмәгыйль улы (2.6.1924, Пенза өлкәсенең Каменка р-ны Ятмис (Кочалейка) а. — 4.11.1997, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (1.3.1944, 31.5.1945, 31.5.1945; 1962 елның 23 сентябрендә 1 нче дәрәҗә орден б-н кабат бүләкләнә), гв. ефрейторы. Туган авылында тракторчы булып эшли. 1942 дән Кызыл Армиядә. 1943 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында: автоматчы, 80 нче һәм 15 нче аерым мотоциклчылар батальоны (38 нче һәм 6 нчы танк армиясенең 5 нче гв. танк корпусы) пулемётчысы. 1 нче һәм 2 нче Украина фронты гаскәрләре составында Киев һөҗүм һәм оборона (1943), Корсунь-Шевченко (1944) һәм Вена (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең ноябрендә Киев шәһәре янында батырлык күрсәтә: разведчиклар төркеме б-н дошман блиндажына үтеп керә, шәхсән үзе 3 солдатны юк итә, «тел»не кулга төшерә; 1944 нең 19 гыйнварында Кобыляки, Ризино (Украина) торак пунктлары янында разведка төркеме б-н дошман тылында кыйммәтле мәгълүматлар җыя һәм аларны вакытында җитәкчелеккә тапшыра; 1945 нең 20 мартында Веспрем (Венгрия) һәм 1945 нең 12 апрелендә Вена шәһәрләре өчен барган сугышларда автомат һәм граната б-н дошманның берничә солдатын юк итә; 1945 нең 19 апрелендә Хагенберг (Австрия) торак пункты янындагы сугышларда шәхсән үзе 8 немец солдатын юк итә һәм берсен әсирлеккә ала. Демобилизацияләнгәннән соң (1945), Каменка (Пенза өлкәсе) шәһәрендә яши. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


Х.И.Янаев.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЯНБУ́ХТИНА** Альмира Гайнулла кызы (28.7.1938, Уфа ш. – 20.11.2018, шунда ук), сәнгать белгече, сәнгать фән. д-ры (2003), БРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2006). И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын тәмамлый (1966). 1966–70 елларда М.В.Нестеров исем. Башкортстан сәнгать музеенда эшли, 1973–77 дә Уфа сәнгать уч-щесендә, Уфа сәнгать ин-тында, 1977–83 тә Уфа нефть ин-тында укыта, 1983–89 да «Агыйдел» сәнгать берләшмәсендә фәнни консультант, 1995 тән Уфа икътисад һәм сервис ун-тында. Рәссамнар берлеге (1973), РФ сәнгать белгечләре ассоциациясе (1992), Халыкара сәнгать тарихчылары һәм тәнкыйтьчеләре ассоциациясе (Париж, 1994) әгъзасы. Хәзерге заман Башкортстан рәссамнарының иҗатын, башкорт халык бизәлеш сәнгатен өйрәнүгә зур өлеш кертә. Уфа «Шәрекъ» традицион һәм заманча сәнгать галереясын оештыручыларның берсе һәм директоры (1990). «Александр Тюлькин» (Л., 1975), «Әхмәт Лотфуллин» («Ахмат Лутфуллин», М., 1975), Уфада басылган «Башкорт өе җиһазларында халык традицияләре» («Народные традиции в убранстве башкирского дома», 1983), «Башкортстанның гамәли сәнгате. XX йөз» («Декоративное искусство Башкортостана. XX век.», 2006), «Михаил Кузнецов. Нәкышь» («Михаил Кузнецов. Живопись», 2010) һ.б. китаплар авторы.

*Әд.:* Х у с н у т д и н о в а Р. Альмира — искусствовед российской провинции // Рампа. 1998. № 7; Ф е н и н а Э.П. Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002; Янбухтина А.Г.: Библиогр. указ. Уфа, 1998.

*Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЯНГИЛДЕ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 26 *км* төньяктарак, Казан — Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 97 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 1648 дән Янгилде Пүчинкәсе буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.дә 2 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 610 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ивановка волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянов, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 273, 1897 дә — 495, 1908 дә — 569, 1920 дә — 478, 1926 да — 414, 1938 дә — 406, 1949 да — 318, 1958 дә — 226, 1970 тә — 191, 1979 да — 140, 1989 да — 92, 2002 дә — 93 кеше.

**ЯНГУ́ЗОВ** Закир Шәриф улы (6.8.1931, Казан — 15.3.2008, С.-Петербург), тарихчы, тарих фән. д-ры (1970), проф. (1971). Казан суворовчылар (1950), Гомель пехота хәрби уч-щеләрен (1952), Ленинград ун-тын (1959) тәмамлый. 1952–54 елларда Белоруссия хәрби округының укчылар взводы командиры. 1960–70 тә СССР ракета гаскәрләрендә сәяси эштә («Плесецк» космодромы, «Капустин Яр» полигоны һ.б.). Бер үк вакытта М.В.Фрунзе исем. Омск югары гомумгаскәри уч-щесендә укыта (1965–67), Ерак Көнчыгыш командирлар югары уч-щесендә марксизм-ленинизм каф. (1967–83, бүленеп, Благовещенск ш.), С.М.Будённый исем. хәрби элемтә академиясендә (1972–74, Ленинград), А.Н.Комаровский исем. Ленинград югары хәрби төзүче-инженерлар уч-щесендә КПСС тарихы кафедралары мөдире (1983). 1983 тә полковник дәрәҗәсендә отставкага чыга. 1984–86 да Витебск мед. ин-тының, 1986–91 дә Пушкино аграр ун-тының (Ленинград өлкәсе) КПСС тарихы кафедралары мөдире. 2002–03 тә Петербург сервис һәм икътисад академиясенең фәлсәфә һәм культурология каф. профессоры. Хезмәтләре хәрби тарихка, совет гаскәр башлыкларына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Особая Краснознамённая Дальневосточная армия на страже мира и безопасности СССР (1929–1938 гг.). Благовещенск, 1970; Созвездие полководцев. Хабаровск, 1972 (автордаш); Забвения нет. Хабаровск, 1990; Волжане в партизанском движении в Белоруссии (июнь 1941 — июль 1944). СПб., 2005.

**ЯНГУРА́ЗОВА** Фәридә Хөсәен кызы (29.8.1922, БАССРның Благовар р-ны Каргалы а. – 16.2.2015, Казан), акушер-гинеколог, сәламәтлек саклау өлкәсе хезмәткәре, ТАССРның атказ. табибе (1966). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1944), БАССРның Миякә район хастаханәсе баш табибе булып эшли. 1950–53 елларда Казан мед. ин-тының акушерлык һәм гинекол. кафедрасында. 1953–58 тә «Бәкер» курорты баш табибе. 1958–84 тә Профсоюзлар курортлары б-н идарә итү буенча Татарстан өлкә советы рәисенең дәвалау мәсьәләләре буенча урынбасары. 1984 тән «Казанский» санаторие акушер-гинекологы. «Авырлы хатыннарны санаторий-курорт оешмалары шартларында сәламәтләндерүнең яңа системасы» хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1996). Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**ЯНГЫННА́Н САКЛАНУ́**, янгын вакытында кешеләрне үлемнән, матди кыйммәтләрне һәм гражданнарның мөлкәтләрен юкка чыгудан саклауны тәэмин итү, ш.у. янгын куркынычын булдырмау буенча профилактик оештыру-техник чаралар системасы.

Рус дәүләтендә түбән баскыч хезмәткәрләрдән торган беренче янгын командасы 16 йөздә Земство приказы (Мәскәү) каршында оештырыла, ул янгыннарны сүндерү өчен җаваплы була. Ләкин 18 йөзгә кадәр шәһәрләрдә һәм авылларда янгынны нигездә анда яшәүчеләр үзләре сүндерә. Янгын казасы турында чаң сугу б-н хәбәр ителә. Ш.у. «янгыннан саклану йөкләмәсе» дә була: һәр 10 йорт кирәк-яраклар б-н бер кеше бирергә тиеш була. Янгынга каршы көрәшкә стрелецлар да җәлеп ителә. Талауларга һәм янгынга каршы көрәш максатында көндез һәм төнлә шәһәр урамнары буйлап күзәтчеләр йөри; 1649 елгы Кануннар мәҗмугасы буенча алар янгын сүндерү кирәк-яракларын (чиләкләр, балталар һ.б.) әзер тотарга тиеш була. 1722 дә С.-Петербургта Баш адмиралтейство каршында махсус янгынга каршы көрәш подразделениесе булдырыла. 1803 тә С.-Петербургта (соңрак — Мәскәүдә) Я.с. хезмәте оештырыла. 19 йөз башында проф. янгын командалары туплана башлый; 1818 дән алар барлык губерна шәһәрләрендә оештырыла. Һәр янгын командасына брандмейстер (брандмайор) җитәкчелек итә. 1845 тә Казанда брандмейстер кул астында 5 ярдәмче, 5 унтер-офицер, 100 рядовой була. 1866 дан янгын командасы шәһәр идарәсе, 1884 тән полиция идарәсе карамагында тора; янгын депосы (бөтен инвентарьлары б-н янгын олавы өчен урын) шәһәр идарәсе карамагында кала. Күзәтчелек тәүлек әйләнә биек каланчадан алып барыла, янгын очрагында объектка чыгу өчен махсус билгеләр б-н хәбәр ителә: көндез кызыл флаг эленә, төнлә яшел фонарь кабызыла. Зур янгын булган очракта чаң сугыла. 19 йөз ахырында Казан полиция участокларында янгын урынына бару өчен һавага төрле комбинацияләрдә махсус шарлар күтәрелә. Шар б-н кызыл флаг яисә яшел фонарь — резерв җибәрү кирәклеген, җәйге җилле көнне күтәрелгән флаг — тиз арада чыгып китү өчен даими әзер торуны аңлата. Янгын командалары ут сүндерү торбалары, мичкәләр, чаннар, күн торбалар, чиләкләр, баскычлар, багорлар, балталар һ.б. б-н җиһазландырыла. 1879 да Казанда янгын олавында 28 су сиптерү, 5 су суырту машинасы һәм 3 кул машинасы, 53 мичкә, 10 багор, 162 ат була; бернечә елдан пар машинасы булдырыла. 1883 тә Тәтеш шәһәрендәге янгын командасында 3 су сиптерү торбасы, 4 мичкә, 10 багор, 7 лом, 12 чиләк, 10 көрәк, 3 баскыч була. Янгын частьлары өчен инвентарьны әзерләү һәм губерналарга җибәрү б-н С.-Петербург һәм Мәскәү янгын деполары шөгыльләнә. Янгын сүндерүдә шәһәр кешеләре дә катнаша, кайбер шәһәр думаларында аларның ни рәвешле катнашулары билгеләнә. Үзләренең су ташу чаралары б-н янгын сүндерүдә катнашучыларга шәһәр бюджетыннан махсус премияләр бирелә; мәс., Тәтештә 1885 тә һәр янгын вакытында ат һәм мичкә бирү 2 сум 50 тиен бәяләнгән. Казанда штаттагы янгын командасы һәм ирекле ялланучылар (якынча 40 кеше) б-н бергә 1892 дән ирекле янгыннан саклану җәмгыяте дә эшли. Казан губернасында авылларда янгынга каршы чаралар күрү б-н земство шөгыльләнә. «Ирекле» командалар авылларда, заводларда, тимер юлда һ.б. урыннарда була. Янгында зыян күргән Я.с. хезмәткәрләренә пенсия бирелә, ә үлем очракларында хөкүмәт «толлар һәм ятимнәрне тәрбия итү» өчен пенсия түли. 19 йөздә янгын очраклары өчен мөлкәтне иминиятләштерүгә махсуслашкан иминият җәмгыятьләре: Россия (1827), Мәскәү (1858) җәмгыятьләре, «Волга» (1871), «Якорь» (1872), «Россия» (1881), Казан үзара иминиятләштерү җәмгыяте (1884) һ.б. барлыкка килә. 1893 тә Россия Я.с. җәмгыяте, 1897 нең 27 июнендә үлем, сәламәтлекне югалту, бәхетсезлек очракларында янгыннан саклаучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү өчен Бөтенроссия Я.с. хезмәткәрләренең үзара ярдәмләшү җәмгыяте (Зәңгәр Хач Җәмгыяте) оештырыла.

Окт. рев-циясеннән соң Я.с.ны оештыруда шактый гына структур үзгәрешләр була. ХСКның 1918 ел 17 апрель Декреты буенча Я.с. Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының Казан губерна башкарма ком-ты коммуналь бүлегенә буйсындырыла. ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР Эчке эшләр халык комис-ты Коммуналь хуҗалык идарәсенең Я.с. бүлеге оештырыла (1923–26 да — ХКС каршында), 1926 дан — ТАССР Эчке эшләр халык комис-ты Коммуналь хуҗалык баш идарәсе каршында (1930–31 дә — ХКС каршында). бүлек ТАССР ХКСның 1931 ел 28 апрель карары б-н ТАССР Коммуналь хуҗалык халык комис-тының Я.с. идарәсе, СССР Эчке эшләр халык комис-тының ТАССР буенча Идарәсенең 1934 ел 28 июль боерыгы б-н бу Идарәнең Я.с. бүлеге (1937 дән — ТАССР Эчке эшләр халык комис-ты каршында), ТАССР Эчке эшләр халык комис-тының 1945 ел 5 гыйнвар боерыгы б-н ТАССР Эчке эшләр халык комис-тының (1946 дан — Эчке эшләр министрлыгы), 1990 нан ТССР, 1992 дән ТР Эчке эшләр министрлыының Я.с. идарәсе итеп үзгәртелә.

1920 еллар ахырында атлы янгын сүндерү олаулары махсус автомашиналарга алыштырыла, 1930 елларда янгын сүндерү техникасы, аларны төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен деполар төзелә. Машина төзелеше өлкәсендәге гомуми үсеш һәм техниканың камилләшүе б-н бәйле рәвештә күпкатлы биналарда, химия пр-тиеләрендә янгын сүндерү өчен төрле җайланмалар барлыкка килә, һавага сиптерелүче механик күбекләр, инерт газлар, ут сүндерә торган порошоклар кулланыла башлый. Я.с. хезмәткәрләре җылылыкны үткәрми торган киемнәр б-н тәэмин ителә.

РФ Президентының 2001 ел 9 ноябрь Указы б-н Дәүләт Я.с. хезмәте подразделениеләре РФнең ТР буенча Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы Баш идарәсенә һәм ТРның Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына буйсындырыла.

ТРда РФнең ТР буенча Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы Баш идарәсе Дәүләт Я.с. хезмәтенең 56 федераль янгыннан саклау подразделениесе (113 янгыннан саклау часте һәм 27 аерым постлар) һәм 45 терр. подразделение (63 янгын сүндерү часте, уку-укыту һәм җитештерү-техник үзәге) эшли. Татарстанда гамәли янгын сүндерү спорты (янгын сүндергәндәге кирәкле күнекмәләрне һәм ысулларны үзләштерү өчен) үсеш кичерә, 1968 дән халыкара ярышлар үткәрелә. ТР терр-ясендә янгын чыгу куркынычын кисәтү һәм янгынга каршы көрәш чараларын федераль, респ-ка карамагындагы, муниципаль оешмалар тормышка ашыра. 1978 дән Казанда Янгыннан саклану музее эшли.

*Әд.:* О р л о в А.П. Опись городских поселений Казанской губернии. К., 1885; З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; З о р и н А.Н. Города и посады дореволюционного Поволжья. К., 2001. *И.А.Новицкая, Е.В.Цыганова.*

**ЯНИ́ЛКИН** Виталий Васильевич (5.1.1954, Аксубай р-ны Чуаш Енорускино а.), физик-химик, химия фән. д-ры (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), Бөтенсоюз мед. инструментлары фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында, 1981–86 елларда СССР ФАнең Себер бүлегендә Иркутск органик химия ин-тында эшли. 1987 дән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында. Хезмәтләре органик кушылмалар, макроциклик кушылмалар, фуллереннар, супрамолекуляр системалар электрохимиясенә карый. Я. органик кушылмаларның төрле класс электрохимик әверелешләренә электрод материалы йогынтысының закончалыкларын тикшерә, сыңар сигма-бәйләнешләр таркалышы шартларында электрон күчешнең гетероген һәм медиатор реакцияләрен өйрәнә. Органик электроника һәм биомедицина өчен наноматериаллар булдыру дәверендә «Фуллеренарның органик чыгарылмалары — «төзелеш блоклары»» эшендә катнашканы өчен



В.И.Яницкий.



Б.Я.Янтимеров.

ТР Дәүләт бүләге бирелә (2010). Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Электрохимическое восстановительное расщепление сигма-связей. $EE_D$ механизм // Электрохимия. 2000. Т. 36, № 2 (автордаш); Электрохимия фуллеренов // Электрохимия органических соединений в начале XXI века. М., 2008; Электрохимия макроциклических соединений // шунда ук. С. 378–429; Обратимость электродных реакций органических соединений // Электрохимия. 2000. Т. 36, № 3.

**ЯНИ́ЦКИЙ** Василий Иванович (15.2.1916, Самара губ., Бөгелмә өязе Иске Куак а. – 30.12.1992, Воронеж өлкәсе, Борисоглебск ш.), Сов. Союзы Герое (12.8.1942), полковник. Тамбов очучылар уч-щесен (1939), Хәрби-һава академиясен (Мәскәү, 1946), Борисоглебск пед. ин-тын (1956) тәмамлый. 1939–41 елларда гражданнар авиациясенең Көнчыгыш-Себер идарәсе очучысы. 1941 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, Көньяк-Көнбатыш фронтында 8 нче армия 52 нче бомбардировщиклар полкы эскадрильясе командиры урынбасары. Белая церковь, Ростов-Дон, Харьков, Воронеж шәһәрләре янында сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 145 сугышчан очыш ясый. 1942 нең 20 июнендә Харьков янындагы сугышларда батырлык күрсәтә, авыр яралана. 1942–44 тә Хәрби-һава академиясе тыңлаучысы. 1946 дан Борисоглебск хәрби-авиация уч-щесендә өлкән укытучы. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. *Ф.Г.Миңнеханов.*

**ЯНИШЕ́ВСКИЙ** Михаил Эрастович (2.12.1871, Казан – 4.12.1949, Ленинград), геолог, палеонтолог, минерал. һәм геол. д-ры (1910), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1941). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1893), шунда ук эшли, геол. кабинеты саклаучысы (1897 елдан). 1902 дән Томск технол. ин-тында, Себердә беренче палеонтология профессоры. 1912 дән С.-Петербургта: геол. ком-тында, бер үк вакытта Психоневрология ин-тында, Югары хатын-кызлар курсларында (1915 тән палеонтология кабинеты мөдире) һәм Петроград (Ленинград) ун-тында (1919 дан Россиядә беренче палеонтология каф. мөдире) укыта. Хезмәтләре палеонтология, стратиграфия, Россия һәм Яңа Зеландиянең файдалы казылмаларын тикшерүгә карый. Палеонтологиядә яңа теоретик юнәлешләр булдыра. Россия биостратиграф-карбонистлар мәктәбен нигезләүче. Бөтенроссия палеонтология җәмгыятен, геол. ком-тын нигезләүчеләрнең берсе. Казан ун-тының Геол. музеенда Я. тарафыннан тупланган фауна коллекциясе саклана.

Х е з м.: Фауна каменноугольного известняка, выступающего по р. Шартымке на восточном склоне Урала // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Имп. Казан. ун-те. 1900. Т. 34, вып. 5; Введение в палеонтологию. Пер. с дополнениями и предисловием книги Г.Штеймана. Томск, 1909 (автордаш).

*Әд.:* С о к о л о в Б.С. Михаил Эрастович Янишевский. К., 2003.

**ЯНКЕЛЕ́ВИЧ** Александр Моисеевич (р. 10.5.1947, Украина ССР, Харьков өлкәсенең Красноград ш.), режиссёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994). Харьков сәнгать ин-тын тәмамлый (1981). Сәхнә эшчәнлеген 1971 елда Харьков курчак театрында актёр буларак башлый. 1981 дән Түбән Тагил курчак театрында баш режиссёр. 1987–99 да Чаллы «Балалар һәм кошлар йорты» («Дом детей и птиц») курчак театрын оештыра һәм аның баш режиссёры була. Я. театрда шактый спектакльләр куя. Аларның һәркайсы образлы стиле, башкарылу манерасы, курчак уйнату алымнары ягыннан үзенчәлекле. Я. төрле һәм сәнгатьчә репертуардан гыйбарәт югары культуралы театр оештыра. Театрда куелган спектакльләр шәһәр тормышында зур мәдәни вакыйга буларак кабул ителә, балалар һәм өлкәннәр арасында уңыш казана. «Кар патшабикәсе» (Е.Л.Шварц, 1988), «Серенада» (С.Мрожек, 1989), «Диңгез култыгы буенда» (А.С.Пушкин әкиятләре буенча, 1993), «Батырлар илендә» (Ә.Фәйзи, 1994), «Ах, минем сөекле Августиным» (Г.Х.Андерсен әкиятләре буенча, 1995), «Ике йөнтәс эт» (С.И.Злотников, 1996) спектакльләре сәнгатьчә форманың төгәл билгеләнеше, мизансценаларның нечкә стилистикасы, образларның поэтик югарылыгы б-н аерылып тора. Театр гастрольләр б-н чыга, театр фестивальләрендә катнаша. 1999–2004 тә Я. Тель-Авивта (Израиль) курчак театрында режиссёр булып эшли, 2005 тән Мәскәү «Жар-птица» курчак театрында сәнгать җитәкчесе.

**ЯНКО́ВСКАЯ** Надежда Федотовна (14.1.1916, Төньяк Маньчжурия, Харбин ш. – 10.8.1998, Казан), анатом, нейрогистолог, мед. фән. д-ры (1965). Казан. мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1939), анатомия кафедрасында калдырыла. 1941–45 елларда 2778 нче эвакогоспитальдә, 1945 тән Казан. мед. ин-тының анатомия кафедрасында. 1965–75 тә Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-ты лаб-ясенең фәнни җитәкчесе. Хезмәтләре кеше бугазын анатомик-нейрогистологик яктан тикшерүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О рецепторной иннервации надхрящницы хрящей гортани // Архив анатомии, гистологии и эмбриологии. 1959. № 8; О чувствительных нервных окончаниях в мышцах гортани человека / Проблемы морфологии нейротканевых и сосудисто-тканевых отношений. К., 1963.

**ЯНКО́ВСКИЙ** Владимир Михайлович (3.3.1940, Казан – 9.7.2001, шунда ук), авиация моторлары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1993), проф. (1995). 1963 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, һава-реактив моторлар каф.мөдире (1988–98), проф. (1998). Хезмәтләре яну процессларын модельләштерүгә һәм җылылык моторларында һәм энергетик җайланмаларда ягулык ягуның оптималь технологияләрен эшләүгә багышлана. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә. Академик ишү буенча халыкара спорт мастеры (1961), 1960–67 дә СССР Олимпия җыелма командасы әгъзасы.

Х е з м.: Исследование массообмена между первичной зоной и струями вторичного воздуха в камерах сгорания ГТД // Изв.вузов. Авиац.техника. 1979. № 1 (автордаш); Моделирование зон горения камер сгорания ГТД // Изв.вузов. Авиац.техника. 1986. № 1; Основы автоматизированного проектирования камер сгорания газотурбинных двигателей. К., 1989.

**ЯНСУА́Р** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 35 *км* көнчыгыштарак, Нырсы елгасы буенда. 2010 елда 166 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 дан рус чыганакларында Нырсурвары Малая Шебулакова тож исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Енсывар, Янцовары буларак мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, өс-баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Покров чиркәве (1884 тә Казан сәүдәгәре П.В.Щетинкин иганәсенә төзелә), Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1884 тә ачыла), ашлык саклау-сату кибете, су тегермәне, тимерче алачыгы, 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1465,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда. 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 244 ир-ат; 1859 да — 624, 1897 дә — 800, 1908 дә — 888, 1920 дә — 997, 1926 дә — 970, 1938 дә — 789, 1949 да — 606, 1958 дә — 585, 1970 тә — 679, 1979 да — 561, 1989 да — 330, 2002 дә — 216 кеше.

**ЯНСУА́Р** (тәхәллүсе, чын исеме һәм фамилиясе Шарова Луиза Николаевна) (13.8.1981, Питрәч р-ны Кавал а.), шагыйрә, әдәбият белгече, филол. фән. канд. (2007). Казан ун-тын тәмамлый (2003). 2010 елдан «Салават күпере», 2011 дән «Ялкын» ж-лары мөхәррире. Дәрдемәнд иҗатын өйрәнә. «Күзен ача умырзая» (1998), «Мин Күкләргә кайтам» (2002), «Болан кызы» (2005), «Без җан өргән учак» (2007) шигырь җыентыклары авторы.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**ЯНСЫБЫ́** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 329 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавы-

на керә, игенчелек, терлек үрчетү, җеп үрү, такта яру, балта эше б-н шөгыльләнә. 1730–41 еллар тирәсендә Я.да Анцуб бакыр кою з-ды, 20 йөз башында 2 мәчет (1800 һәм 1874 тә төзелә) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1702 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Күкшел волостенда. 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1884 тә — 933, 1905 тә — 1156, 1920 дә — 1198, 1926 да — 1103, 1938 дә — 910, 1949 да — 532, 1958 дә — 498, 1970 тә — 499, 1979 да — 451, 1989 да — 332, 2002 дә — 352 кеше.

**ЯНТИМЕ́РОВ** Булат Янбулат улы (1915, хәзер Төмән өлкәсенең Исәт р-ны Югары Йөгәнле а. – 26.6.1944, Белоруссия ССРның Витебск өлкәсе Санники а.), Сов. Союзы Герое (22.7.1944, үлгәннән соң), капитан. Төмән пед. уч-щесен (1936), Төмән хәрби-пехота уч-щесен (1941) тәмамлый. Укытучы булып эшли. 1937–40 елларда һәм 1941 нең июненнән Кызыл Армиядә. Совет-фин сугышында катнаша. 1942 нең мартыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 938 нче укчы полкта (43 нче армиянең 306 нчы укчы дивизиясе) батальон командиры урынбасары. 1 нче Балтыйк буе фронты гаскәрләре составында Балтыйк буе һөҗүм операциясендә катнаша (1944). 1944 нең 24–26 июнендә Шарипино а. (Белоруссия ССРның Витебск өлкәсе Бешенковичи р-ны) янында Көнбатыш Двина елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: батальонның кичүне оста оештыруы аркасында, плацдарм яулап алына, аннан соң дошманның берничә контрһөҗүмен кире кагып, Я.ның подразделениесе һөҗүм башлый; Я. сугышта һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медаль б-н бүләкләнә. Туган авылында мәктәпкә, район үзәгендәге бер урамга Я. исеме бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЯНТУГА́Н** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 32 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасы бассейнында. 2010 елда 473 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, май з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1652 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Урта Чепкас буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашман хезмәтен үти, игенчелек, терлек үрчетү, балта эше һәм он тарту, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да волость идарәсе урнаша; 4 мәчет, 3 мәдрәсә, 13 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3053,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Янтуган волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 27 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 1013, 1897 дә — 1395, 1913 тә — 1404, 1920 дә — 1691, 1926 да — 1420, 1938 дә — 1125, 1949 да — 894, 1958 дә — 783, 1970 тә — 1133, 1979 да — 707, 1989 да — 574, 2002 дә — 474 кеше.

**ЯНУРЫ́С** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 7 *км* төньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 361 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1719 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.та мәчет, мәдрәсә, ашлык саклау-сату һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1177 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Языково волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 519, 1897 дә — 742, 1906 да — 863, 1926 да — 800, 1949 да — 803, 1958 дә — 623, 1970 тә — 521, 1979 да — 459, 1989 да — 424, 2002 дә — 387 кеше.

**ЯНУТСЫМА́Н ЭТ** (Nyctereutes procyonoides), этсыманнар семьялыгыннан имезүче ерткыч хайван. Я.э.нең табигый ареалы — РФнең Ерак Көнчыгышы (Уссури крае), ш.у. Кытай, Корея, Япония, Төньяк Вьетнамның урманлы өлкәләре. 1920 еллар ахырында Я.э. СССРның төрле районнарына таратыла. 1934 тә Татарстанга китерелә һәм Алексеев р-нына 100 Я.э. җибәрелә, хәзер бөтен җирдә диярлек киң таралган. Тышкы кыяфәте б-н төлкене хәтерләтә. Гәүдәсенең озынлыгы 80 *см* га, койрыгы 15–25 *см* га кадәр, авырлыгы 8–10 *кг*. Кыска аяклы, очлы танаулы һәм кара-көрән кыллар катыш соргылт-тонык сары төстәге бик озын (12 *см* тирәсе) йонлы. Танавындагы кararак төстәге «битлек» һәм башының аксыл төстә булуы Я.э.не янутка охшата (исеме шуннан). Гәүдәсенең аскы өлеше саргылт-көрән, аяклары кара-көрән. Кечерәк мәйданлы ачык урыннары булган дымлы катнаш һәм яфраклы урманнарда, елга үзәннәрендәге һәм сазлык кырыйларындагы куаклыкларда оялый. Төрле типтагы яшеренү урыннары: җәен — өннәр, кышын — үсемлекләр б-н капланган ерымнар, тугайлы урманнар, тау битләрендәге куышларны сайлый; бурсык ояларын файдалана. Җәйге чорда бөҗәкләр, бакалар, вак кимерүчеләр, моллюсклар, балык б-н туклана. Язын һәм көзен рационда үсемлек азык (үсемлекләрнең вегетатив өлешләре, бүлбе, тамырча, җиләк, кыяклылар бөртекләре, чикләвекләр) өстенлек итә. Гадәттә, ноябрьдә йокыга тала, кагыйдә буларак, февраль-мартта уяна. Кышкы йокы тәмамланганнан соң, көннәр җылыну б-н кушылу вакыты башлана. Буазлык чоры — 60–64 көн. 5–7 (кайвакыт 11–16 га кадәр) бала китерә. Җәй ахырына кадәр Я.э. балалары олы затлар б-н яши, сентябрь-октябрьдә мөстәкыйль яшәүгә күчәләр. Җенси яктан 8–10 айда җитлегә. 11 елга кадәр яши. Я.э.нең иң куркыныч дошманнары — бүре һәм селәүсен. Кайвакыт балалары ерткыч кошларның корбаны була. Я.э. — мех кәсепчелеге объекты. Кәсепчелек кошлары — үрдәкләр, көртлекләр һ.б.ның йомыркаларын һәм ояларын юк итеп, сунарчылык хуҗалыгына зыян китерә.

**ЯНУЧА́Н СЛА́НЕЦЛАР**, корылай куганда шактый күләмдә сумала (составы буенча нефтькә якын) бирүче файдалы казылма. Күбрәк минераль (кальцит, доломит, гидрослюда, кварц һ.б.) һәм органик (суүсемнәр, үсемлек калдыклары) өлешләрдән тора. Коңгырт яки соры төстә, кипкәч яссы юка кисәкләргә аерыла. Сланец сумаласы б-н исәпләгәндә дөньякүләм запас 550 млрд. *т* тәшкил итә. Төп запаслары АКШ, Бразилия, Эстония, Россиядә (якынча 20 млрд. *т*). Эстония, Кытай һәм РФдә сәнәгать күләмендә чыгарыла. ТРның көньяк-көнбатышында мәйданы 1–12 *км*$^2$ булган югары юра яшендәге 6 ятма ачыкланган, аларда Я.с. катламының калынлыгы 0,13–1,27 *м* һәм запасы 59 млн. *т*



ТР неоген утырмаларының янучан сланецлары (Гөлшурма авылы)

тәшкил итә; мезозой утырмаларында (түбән акбур, югары юра) якынча 25 млн. *т* запас б-н 2 чыганак ачыклана. Я.с.катламының гомуми калынлыгы 7,5 *м* га, яну җылылыгы 5,5 *МДж/кг* га кадәр. Я.с.ның көллелеге 22,75 тән 85,71% ка кадәр, очучан компонентлар — 10,32–77,25%, күкерт — 0,67–7,9%, $P_2O_5$ — 0,34–1,05%, $K_2O$ — 1,38–2,26%, $SO_3$ — 9,14%. Шулай ук составында микроэлементлар (Mn, Mo, Cu, Ni, Co, V) бар. Идел һәм Зөя елгаларының субүләрендәге югары юра күмер-балчыклы сланецлары аеруча гамәли әһәмияткә ия. Я.с.ның фосфоритлардан һәм глауконитлы комнардан турыдан-туры якын ятуы аларны ачык ысул б-н бер үк вакытта эшкәртергә мөмкинлек бирә. Я.с., ягулык буларак, комплекслы ашламалар җитештерүдә кулланыла; янучан газ, сыек нефть продуктлары (мазут), төзелеш материаллары алуда чимал булып тора; сланец көленнән химия продуктлары (фенол, ихтиол һ.б.) алалар. Җир астыннан газ үткәрү юлы б-н нефть һәм газ алу өчен чимал булырга мөмкин.

*Әд.:* Хрусталёва Г.К., Воробьёва Л.А., Медведева Г.А. Минеральное сырьё. Горючие сланцы: Справ. М., 1997; Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

**ЯНУЧА́Н ТАБИГЫ́Й ГАЗЛА́Р**, метан рәтендәге углеводородлар һәм углеводород булмаган компонентлар катнашмасы, ирекле халдәге җыелмалар, ш.у.эремә (нефть һәм катлам суларында), токымнар тарафыннан йотылган һәм каты (газ гидратлы ятмаларда) халәттә җир кабыгының утырма тышлыгында очрыйлар. Метан рәтендәге углеводород-

лар — метан (85–90%), этан, пропан, бутан һәм ара-тирә пентаннан, углеводород булмаган компонентлар, башлыча азот, углекислый газ, су парларыннан һ.б.дан гыйбарәт. Составындагы авыр углеводородларның, азот һәм углекислый газның күләме артык булуы б-н бәйле, Я.т.г.дагы су парлары (газ дымлылыгы) аларны транспортлау һәм эшкәртүне кыенлаштыра. Газлардагы дымны бетерү өчен төрле физик-химик киптерү алымнары кулланалар. Я.т.г.ның яну җылылыгы — 32,7 *МДж/м*³. Күпчелек Я.т.г. ятмалары утырма токымнар б-н бәйле һәм коллекторлардан, аны чикләүче япма токымнардан торучы табигый резервуарларга туры килә. Я.т.г. ятмалары катлам басымы астында яталар. Газ ятмаларының урнашуында, ш.у. нефтьләрдәге кебек фәзаи яраклашу яки зоналылык күзәтелә. Ачыкланган Я.т.г. запасларының 90% тан артыгы чиста газ яки газ конденсаты чыганакларында тупланган. Җир шарында ачыкланган газ запасларының 70 трлн. *м*³ дан артыгы, нигездә, уникаль (1 трлн. *м*³ дан күбрәк) һәм бик зур (0,1–1,0 трлн. *м*³) газ һәм газ конденсатлы чыганакларда тупланган. Я.т.г.ны чыгару үз эченә газларны җир астыннан чыгаруны, транспортлау өчен җыюны һәм әзерләүне ала, ул исә үткәргеч торбалар магистрале буенча (аерым алганда, пр-тиеләрне һәм торак пунктларны тәэмин итү өчен) яисә махсус танкерларда су транспорты б-н башкарыла. Татарстан терр-ясендә Я.т.г. респ-каның көнчыгышында Татар гөмбәзенең Көньяк өлеше чикләрендә ачыкланган һәм $C_4$ кә кадәр туендырылган һәм туендырылмаган компонентлары, ш.и. этилен һәм пропилен б-н кристаллик нигездә бирелә. Токымнарда углеводородларның күләме $16 \cdot 10^{-4}$ нан $9000 \cdot 10^{-4}$ *см*³/*кг* га кадәр тирбәлә. Уфа ярусының югары өлешендәге комташларда утырма тышлыкта углеводород газы ятмасы ачыклана. Югары нәтиҗәле җылылык бирүче һәм метанол, формальдегид, серкә к-тасы, ацетон һ.б. органик кушылмалар алу өчен кыйммәтле химик чимал буларак файдаланыла.

*Әд.:* Ю с у п о в Б.М., В е с е л о в Г.С. Размещение нефтяных месторождений Татарии. М., 1973; Горная энциклопедия. М., 1984. Т. 1.

*Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**ЯНУЧА́Н ФАЙДАЛЫ́ КАЗЫЛМАЛА́Р**, янган вакытта җылылык бүлеп чыгаручы табигый органик кушылмалар. ТРда Я.ф.к. — *нефть*, табигый газлар, *битумнар*, *торф*, *казылма күмерләр*, *янучан сланецлар*.

**Я́НШИНА** (Биккенина) Фидан Тәүфикъ кызы (28.5.1933, Үзбәкстан ССРның Хива ш. — 17.9.2011, Мәскәү), геолог-нефтьче, филос. фән. д-ры (2000). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), СССР ФАнең нефть ин-тында эшли. 1963 елдан Новосибирск ун-тында укыта. 1983 тән СССР ФАнең Минерал. музеенда (Мәскәү), 1988 дән Геохимия һәм аналитик химия ин-тының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре геологиягә, фән тарихына карый. Я. Көнбатыш Себер нефть ятмаларының һәм Ленинград өлкәсе дүртенчел чор утырмаларының яту үзенчәлекләрен ачыклый. В.И.Вернадский һәм А.Л.Яншин хезмәтләренең библиографиясен төзи, аларның эшчәнлегенә бәя бирә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эволюция взглядов В.И.Вернадского на биосферу и развитие учения о ноосфере. М., 1996; А.Л.Яншин: Из неопубликованного. М., 2003.

**ЯНШЫ́К** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 12 *км* төньяктарак, Бәтке елгасы буенда. 2010 елда 110 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1565–67 елларда Пустошь Дертули Апшеик, 1649 дан Дертюли Радовская тож исемнәре б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чыпта-кап сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.та мәчет, мәдрәсә, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 601 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 337, 1897 дә — 623, 1908 дә — 703, 1920 дә — 737, 1926 да — 670, 1949 да — 529, 1958 дә — 446, 1970 тә — 388, 1989 да — 163, 2002 дә — 163 кеше.

**ЯНЪЙӨЗӘРЛӘ́Р**, т ө р л е а я к л ы к ы с л а с ы м а н н а р (Amphipoda), югары төзелешле кыслалар отряды. Якынча 4500 төре билгеле, күбесе — диңгез (литоральдән абиссальгә кадәр), бентос (ш.и. грунтта казынучылар) һәм планктон формалар. Төче су формалары арасында эндемик Я.гә аеруча Байкал күле бай — 240 төр. Татарстан терр-ясендә төче су югары төзелешле кыслалар арасында төрләр саны буенча Я. 1 нче урынны били; аларның күпчелеге: 7 төр — гаммаридлар (Gammaridae), бер төре корофиидлар (Corophiidae) семьялыкларына карый. Зур Куйбышев (6 төр) һәм Түбән Кама (4 төр) сусаклагычларында яшиләр (иң киң таралганнары — Dikerogammarus haemobaphes Eichw. һәм Pontogammarus obesus Sars.). Бары тик бер гаммарид төре (Rivulogammarus pulex L.) генә күл һәм буаларда очрый. Гаммаридларның гәүдәсе ян-яктан, ә корофиидлар (Corophium curvispinum Sars.) вәкиленең гәүдәсе өстән аска таба кысылган. Озынлыгы 1–2 *см*. Башы тоташып үскән 5 баш һәм 1 күкрәк сегментларыннан тора, утырма күзләр һәм 2 пар антенналар (мыекчалар) бар. Күкрәге 7 буынтыктан тора, аларның һәркайсы берәр пар очлык: беренче 2 се — тоту (кыскычлар б-н), соңгы 5 се — йөрү очлыклары. Ана затларның күкрәгендә оя камерасы урнашкан. Корсак өлеше һәрберсе ике тармаклы: өч — алгы йөзә һәм өч — арткы сикерә торган аяклы 6 буынтыктан тора. Корсагының соңгы буынтыгы артында зур булмаган пластинка — тельсон урнашкан. «Я.» бик үк төгәл исем түгел — ян б-н алар бары тик сай сулыкларда гына йөзәләр. Һәртөрле азык б-н туеналар. Күп кенә балыкларның азыгы булып торалар, шул сәбәпле климатка яраклаштыру өчен перспективалы.

*Әд.:* Б и р ш т е й н Я.А. Высшие раки (Malacostraca). Жизнь пресных вод СССР. М.–Л., 1940. Т. 1; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Определитель пресноводных беспозвоночных России и сопредельных территорий. Т. 2. Ракообразные. СПб., 1995.

*Р.М.Сабиров.*

**ЯНЫ́КИН** Николай Фёдорович (22.8.1931, Яшел Үзән р-ны Осиново а.), токарь, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1981). 1944–93 елларда «Серго исем. завод» ҖБдә эшли. Дәүләт бүләге хезмәттәге алдынгы казанышлары, хезмәт процессларын комплекслы камилләштерү нигезендә машиналар төзүдә югары нәтиҗәлелек һәм сыйфатлы эше өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**Я́НЫШЕВЛАР**, татар морзалары нәселе. Нәсел башы — Усы даругасы Карышбаш авылыннан (хәзер БРның Балтач р-ны Үрге Карышбаш а.) мишәр старшинасы Яныш Абдуллин (1862–?); 1743 елда Усы даругасы Озёрки авылында яши. 1735–40, 1747, 1755–56 дагы башкорт-татар күтәрелешләрен бастыруда катнаша. Вазифасыннан законсыз файдаланганы өчен эше Сенатның Башкорт эшләре буенча комиссиясендә тикшерелә. Иң билгеле балалары: **Солтанморат**, Солтанморат авылына (хәзер БРның Аургазы р-ны) нигез сала; **Әхмәр**, 1773–75 тәге Крәстияннәр кузгалышында җирле халыкның күтәрелешләрен бастыруда катнаша. Алтын медаль б-н бүләкләнә; **Бәхтияр**, старшина ярдәмчесе, ш.у. 1773–75 тәге Крәстияннәр кузгалышын бастыруда катнаша, поход старшинасы (1776 дан), Себер даругасы мишәр командасы старшинасы (1777 дән), Бөре өязе мишәр командалары старшинасы (1790 еллар). 1775 тә Бәхтияр С.-Петербургта «башкорт депутациясе» составында император Екатерина II хозурында була. Алтын медаль б-н бүләкләнә (1776); **Нигъмәтулла Солтанморатов**, поручик, 1773–75 тәге Крәстияннәр кузгалышы вакытында халык күтәрелешләрен бастыруда катнаша, Себер даругасы мишәр командасы старшинасы. Алтын медаль б-н бүләкләнә. Аның исемен Нигъмәтулла авылы йөртә (хәзер БРның Әлшәй р-нында). 18 йөз ахыры — 19 йөз башында Я. нәселенә дворянлык дәрәҗәсе бирелә; **Рәхмәтулла Солтанморатов**, улы Шәмселмөлек б-н бергә 19 йөз уртасында Оренбург губернасы дворяннар шәҗәрәләре китабының 3 нче бүлегенә кертелә. 1874 тә зауряд-хорунжий Нуретдин Я.ның милкендә Уфа губернасының Бөре өязендә 500 дис. җир һәм 1 мең дис. урман була.

*Әд.:* Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006; Башкирская энциклопедия. Уфа. 2012. Т. 7.

**ЯҢА́**, к. *Новый*, Мамадыш р-ны.

**«ЯҢА́ АВЫ́Л»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1930 елның 1 гыйнварыннан 1933 нең мартына кадәр Горький шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, 5 көнгә 1 тапкыр басыла, барысы 231 саны чыга. ВКП(б)ның Түбән Новгород өлкә ком-тының татар секциясе, 1932 дән мәдәният һәм пропаганда бүлеге, 1933 тән

ВКП(б)ның Горький өлкә ком-ты органы. Мөхәррирләре — Р.Аббасов, Г.Гыйзәтуллин. Актив авторлары арасында — С.Бакиев, Х.Газизов, В.Садри, Д.Фатыйхи, Ш.Хөсни һ.б. Газетада иҗтимагый-сәяси тематикага зур урын бирелә. 1932 нең ахырыннан үзенчәлекле язмаларның саны кими, төп урын совет хөкүмәтенең карарларына, агитация-пропаганда материалларына бирелә. Басма җирле совет оешмалары эшчәнлеген активлаштырырга, 4 елга 1 нче бишьеллык планнарын үтәргә, «солтангалиевчелек» б-н көрәшергә чакыра. «Партия тормышыннан», «Җирле советлар турында», «Эшчеләр тормышы», «Авыл хуҗалыгы», «Дингә каршы», «Яңалиф» рубрикаларында большевиклар партиясе тарихы, күмәкләштерү барышы, комсомол һәм пионер хәрәкәте һ.б. турындагы язмалар урнаштырыла. Төбәк мәсьәләләренә караган язмалар, нигездә, кыскача мәгълүмати характерда була. Аларда татар балалар бакчалары, мәктәпләр, клублар, театрлар ачылу һәм аларның эше турында хәбәр ителә. Совет җәмгыятенә, кешеләр хезмәтенә дан җырлаган җирле яшь шагыйрьләр (Б.Әмин, Г.Галләмов, Н.Таһири, М.Фәйзи, Д.Фәтхи һ.б.) һәм язучыларның (Х.Мозаффаров, З.Хәмидуллин һ.б.) әсәрләре басыла. «Я.а.» төбәктә бердәнбер татар телендәге газета була.

*З.З.Гыйләҗев.*

**«ЯҢА́ АВЫ́Л»**, газета; к. «*Кызыл таң*».

**ЯҢА́ АЙМА́Н**, авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 31 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 92 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 19 йөзнең соңгы чирегендә нигез салына. 20 йөз башында Я.А.да мәчет (1894 тә төзелә) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1839 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Пучы, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1913 тә — 605, 1920 дә — 445, 1926 да — 406, 1938 дә — 349, 1949 да — 258, 1958 дә — 259, 1970 тә — 239, 1979 да — 184, 1989 да — 88, 2002 дә — 117 кеше.

**ЯҢА́ АКСУБА́Й** авылы, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 7 *км* көнчыгыштарак, Киса елгасы (Олы Сөлчә бассейны) буенда. 2010 елда 427 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, кошчылык, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Аксубай исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 җил тегермәне, тимерче алачыгы, йон тетү, май язу, дегет кайнату, йонману йорты, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1524 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостенда. 1920 дән ТАССРның — Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 43 ир-ат; 1859 да — 781, 1897 дә — 834, 1908 дә — 811, 1920 дә — 820, 1926 да — 686, 1938 дә — 609, 1949 да — 649, 1958 дә — 548, 1970 тә — 642, 1979 да — 630, 1989 да — 421, 2002 дә — 397 кеше.

**ЯҢА́ АКХУҖА́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаж елгасы бассейнында. 2010 елда 255 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1864 тә Иске Акхуҗа һәм Көчек авылларыннан күченүчеләр нигез сала, кырчылык, терлек үрчетү, чабата үреп сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, рус-татар земство мәктәбе (1885 тә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1765 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Салагыш волостенда. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1887 дә — 528, 1905 тә — 746, 1920 дә — 828, 1926 да — 999, 1938 дә — 929, 1958 дә — 508, 1970 тә — 546, 1989 да — 366, 2002 дә — 272 кеше.

**ЯҢА́ АЛА́Н**, к. *Яңа Поляна*.

**ЯҢА́ АЛА́Н** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 45 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2010 елда 52 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1740 та нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.А.да чиркәү (1903–04 тә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (19 йөз ахыры ачыла), 2 су тегермәне, ашлык саклау-сату, 5 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2059,1 дис. тәшкил итә. Гражданнар сугышы елларында Я.А. «*Сәнәкчеләр» фетнәсенең* үзәге була. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Троицк-Йосып волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 293, 1795 тә — 218, 1816 да — 306, 1834 тә — 461, 1859 да — 559, 1897 дә — 1036, 1913 тә — 1226, 1920 дә — 1242, 1926 да — 1065, 1938 дә — 898, 1949 да — 669, 1958 дә — 572, 1970 тә — 390, 1979 да — 236, 1989 да — 70, 2002 дә — 50 кеше.

**ЯҢА́ АЛЕКСА́НДРОВКА** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 9 *км* көньяктарак, Кече Сөлчә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 69 кеше (руслар, украиннар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1920 дә нигез салына. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Мукшы волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1920 дә — 327, 1926 да — 343, 1938 дә — 369, 1958 дә — 172, 1970 тә — 168, 1979 да — 129, 1989 да — 70, 2002 дә — 76 кеше.

**ЯҢА́ АЛЕКСА́НДРОВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зәй елгасы (Дала Зәенең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 293 кеше, ш.и. руслар 68% яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1880 дә нигез салына. 20 йөз башында Я.А.да земство мәктәбе, 2 су тегермәне була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1668 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумароково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1910 да — 518, 1920 дә — 511, 1926 да — 507, 1938 дә — 401, 1949 да — 266, 1958 дә — 243, 1970 тә — 224, 1979 да — 198, 1989 да — 311, 2002 дә — 317 кеше.

**ЯҢА́ АЛЕКСА́НДРОВКА** посёлогы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 19 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан – Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 57 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 277,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1859 да — 58, 1884 тә — 123, 1897 дә — 182, 1906 да — 223, 1913 тә — 236, 1920 дә — 228, 1926 да — 169, 1938 дә — 171, 1949 да — 202, 1958 дә — 117, 1970 тә — 89, 1979 да — 64, 1989 да — 45, 2002 дә — 70 кеше. Я.А.да С.М.Киров (С.-Петербург) исем. Мария акад. театры дирижёры В.Федотов туган.

**ЯҢА́ АЛЕКСА́НДРОВКА СӨЗӘКЛЕГЕ́**, ландшафтлы табигать истәлеге, Бөгелмә р-нында, Яңа Александровка авылыннан төньяк-көнчыгыштарак. 1991 елда билгеләнә. Мәйданы 44,2 *га*. Зәй елгасы (Дала Зәе кушылдыгы) үзәненең көнбатыш сөзәклегендә үсемлекләрнең дала төрләре һәм 70–80 яшь-



Яңа Александровка сөзәклеге.

лек ялгыз каеннар үсүче участокны били. Биеклекләрнең абс. билгесе 300 *м* га җитә. Язгы адонис үсә (популяция тыгызлыгы 1*м*² да 2,5 данә). Литвинов тәңкә яфрагы, шарсыман дөгәнәк очрый. Дару үсемлекләре резерваты буларак фәнни-гамәли әһәмияткә ия.

**ЯҢА́ АЛПА́Р** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 18 *км* көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 164 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1930 елларда Иске Алпарның бер өлешеннән төзелә. Оешкан көненнән Әлки р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1938 дә — 450, 1949 да — 413, 1958 дә — 381, 1970 тә — 467, 1979 да — 377, 1989 да — 264, 2002 дә — 188 кеше.

**ЯҢА́ АНЗИ́РКА** (Әнҗерә) авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 40 *км* көнбатыштарак, Әнҗерә елгасы (Вятканың сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 74 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Казан Богородица чиркәве (1848–65 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство уч-щесе, китапханә (1907 дә ачыла), тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2041,1 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 688, 1897 дә — 950, 1905 тә — 919, 1920 дә — 835, 1926 да — 983, 1938 дә — 1005, 1958 дә — 290, 1970 тә — 205, 1979 да — 139, 1989 да — 90, 2002 дә — 83 кеше.

**ЯҢА́ АРЫ́Ш** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бәтке елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 759 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз уртасына кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1045 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 78 ир-ат; 1859 да — 858, 1897 дә — 1151, 1908 дә — 1420, 1920 дә — 1361, 1926 да — 1239, 1949 да — 1201, 1958 дә — 1023, 1970 тә — 1235, 1989 да — 841, 2002 дә — 803 кеше.

**ЯҢА́ АШЫ́Т** авылы. Арча р-нында, Арча шәһәреннән 46 *км* төньяктарак, Мари Респ-касы чигендә. 2010 елда 152 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шушма елгасы буендагы авыл исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 318,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 125 ир-ат; 1859 да — 134, 1897 дә — 253, 1908 дә — 321, 1920 дә — 350, 1926 да — 355, 1938 дә — 364, 1949 да — 347, 1958 дә — 313, 1970 тә — 244, 1979 дә — 221, 1989 да — 155, 2002 дә — 139 кеше.

**ЯҢА́ ӘЛЕ́М** авылы, Акташыш р-нында, Акташыш авылыннан 6 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 1309 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18-19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә. 1773–75 тәге Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Я.Ә.дә 2 мәчет, мәдрәсә, мәктәп, кредит ширкәте, 2 җил тегермәне, 4 ярма яргыч, тимерче алачыгы эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 6664,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Актаныш волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә,1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 373 ир-ат; 1859 да — 527, 1870 тә — 1349, 1884 тә — 1532, 1897 дә — 2044, 1906 да — 1822, 1933 тә — 2599, 1920 дә — 2435, 1926 да — 2201, 1938 дә — 2122, 1949 да — 1693, 1958 дә — 1552, 1970 тә — 1772, 1979 дә — 1789, 1989 да — 1371, 2002 дә — 1247 кеше.

**ЯҢА́ ӘЛМӘЛЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 7 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чынлы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 776 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 1723 кә кадәр нигезләнә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Новый Ильмовый Куст исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре (1797 гә кадәр — сарай) катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек, агач эшкәртү һәм тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү, 2 мәктәп, 27 сәүдә-сәнәгать кибете була; җомга базары эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1740,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда. 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 888, 1897 дә — 1328, 1913 тә — 1604, 1920 дә — 1532, 1926 да — 1515, 1938 дә — 1904, 1949 да — 1475, 1958 дә — 1634, 1970 тә — 1616, 1979 да — 1348, 1989 да — 878, 2002 дә — 786 кеше.

**ЯҢА́ ӘЛМӘЛЕ́** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 12 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 685 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, чөгендер үстерү. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1730–40 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Калмыкова, Новый Климовый Куст исемнәре б-н билгеле. 1860 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1899 да ачыла), 1 шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1294 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Кутәмә волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 85 ир-ат; 1859 да — 489, 1897 дә — 956, 1908 дә — 1067, 1920 дә — 1198, 1926 да — 1055, 1949 да — 1218, 1958 дә — 1241, 1970 тә — 1405, 1979 дә — 991, 1989 да — 623, 2002 дә — 626 кеше.

**ЯҢА́ ӘЛМӘ́Т** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 51 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мораса елгасы буенда. 2010 елда 422 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ә.тә 2 тимерче алачыгы, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2981 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 146 ир-ат; 1859 да — 1067, 1897 дә — 1726, 1908 дә — 2005, 1920 дә — 1961, 1926 да — 1240, 1938 дә — 927, 1949 да — 764, 1958 дә — 1070, 1970 тә — 1119, 1979 дә — 801, 1989 да — 481, 2002 дә — 497 кеше.

**ЯҢА́ ӘМЗӘ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 60 *км* төньяк-көнбатыштарак, Гәрәй елгасы буенда. 2010 елда 435 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 1740 та нигез салына. 1860 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрче-

тү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ә.дә тимерче алачыгы, 6 вак-төяклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1554 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 68 ир-ат; 1859 да — 713, 1897 дә — 1233, 1908 дә — 1447, 1920 дә — 1459, 1926 да — 795, 1938 дә — 782, 1949 да — 666, 1958 дә — 711, 1970 тә — 942, 1979 дә — 753, 1989 да — 493, 2002 дә — 499 кеше.

**ЯҢА́ ӘНҖЕРӘ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 36 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 41 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Әлки р-нында. 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1938 дә — 147, 1949 да — 182, 1958 дә — 177, 1970 тә — 199, 1979 дә — 102, 1989 да — 47, 2002 дә — 44 кеше.

**«ЯҢА́ ӘНИ́С»** алмагач сорты, 1971 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Г.И.Розанова тарафыннан Идел буе ренетын алсу әнис б-н кушып чыгарыла. Кышка чыдам һәм югары уңыш бирә (бер агачтан 160 *кг*), 4 нче елында җимеш бирә башлый. Кутыр авыруы б-н аз зарарлана. Агач уртача биеклектә, кысылган-түгәрәк, күп яфраклы ябалдашлы. Берьеллык үрентеләренең һәм 2–3 еллык ботакларының кайрысы кызыл-көрән төстә, күпьеллыкларының — ачык көрән төстә, ясмыкчалары ак, озынча. Кәүсәсе ачык көрән, яшь агачларныкы яшькелт төстә. Яфраклары зур түгел, озынча-түгәрәк, куе яшел төстә, нык ялтыравыклы, түбәнге ягы бик аз төкле. Яфрак төбе йөрәксыман, очы түгәрәк-чөйсыман. Яфрак сабагы уртача озынлыкта (2,5 *см*), аз төкле. Төпчек яфраклары юк. Җимешләре түгәрәк, вак (60–70 *г*), җете кызыл төстә. Җимеш йомшагы вак бөртекле, сусыл, ак, яшькелт төсмерле, тәме әчкелтем-баллы. Җимеш сабагы озын, куе шәмәхә төстә, җимеше б-н нык тоташкан. Җимешләре сентябрьнең 3 нче декадасында өлгерә, мартка кадәр саклана, яңа өлгергән һәм эшкәртелгән хәлдә кулланыла. Кимчелеге — үзенчәлекле әнис тәме юк. ТРда һәм Урта Идел янындагы төбәкләрдә таралган.

**ЯҢА́ ӘХМӘ́Т** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 3 *км* төньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 251 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новое Ахметбызово исеме б-н билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2368,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәтмулла волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 77 ир-ат; 1920 дә — 631, 1926 да — 613, 1938 дә — 661, 1949 да — 555, 1958 дә — 479, 1970 тә — 412, 1979 дә — 318, 1989 да — 237, 2002 дә — 257 кеше.

**ЯҢА́ БАЙЛА́Р** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 35 *км* көнчыгыштарак, Тиргәвеш елгасы буенда. 2010 елда 171 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. Мәчет. 18 йөздә — 19 йөз башында Иске Байлар авылыннан чыгучылар нигез сала. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Б.да мәчет (1846 дан мәгълүм), мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1616 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күсәкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1976 ның 6 июненнән — Күзкәй, 1984 нең 4 июненнән — Тукай р-нында, 1991 нең 14 мартыннан кабат торак пункт буларак теркәлә. Халык саны: 1858 дә — 296, 1870 тә — 463, 1884 тә — 492, 1897 дә — 725, 1906 да — 842, 1913 тә — 854, 1920 дә — 833, 1926 да — 508, 1938 дә — 479, 1949 да — 369, 1970 тә — 340, 1989 да — 179, 2002 дә — 166 кеше.

**ЯҢА́ БАЙСА́Р** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 34 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Сөн елгасы буенда. 2010 елда 132 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1889 да нигез салына. Халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1422 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш,1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1897 дә — 207, 1906 да — 227, 1913 тә — 202, 1920 дә — 305, 1926 да — 317, 1938 дә — 322, 1949 да — 206, 1958 дә — 197, 1970 тә — 211, 1979 да — 153, 1989 да — 104, 2002 дә — 102 кеше.

**ЯҢА́ БАЛАНДА́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 37 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Кәкрекүл волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 204, 1938 дә — 244, 1949 да — 188, 1958 дә — 228, 1970 тә — 196, 1979 да — 111, 1989 да — 34, 2002 дә — 46 кеше.

**ЯҢА́ БАЛЛЫКҮ́Л** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 5 *км* көнбатыштарак, Нохрат елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 72 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек. Башлангыч мәктәп, китапханә. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. 1860 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Б.дә мәчет, мәктәп, 3 җил тегермәне, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 803,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 107 ир-ат; 1859 да — 374, 1908 дә — 615, 1920 дә — 574, 1926 да — 424, 1938 дә — 381, 1949 да — 260, 1958 дә — 216, 1970 тә — 254, 1979 да — 143, 1989 да — 84, 2002 дә — 105 кеше.

**ЯҢА́ БАЛТА́Ч** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 21 *км* көнбатыштарак, Шәбез инеше буенда. 2010 елда 139 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау, умартачылык. Урта мәктәп. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Б.та мәчет (1894 тә төзелә), 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1609,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Такталачык (1913 кә кадәр — Шәрип) волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 66, 1816 да — 48 ир-ат; 1834 тә — 102, 1859 да — 187, 1870 тә — 192, 1884 тә — 210, 1897 дә — 325, 1913 тә — 372, 1920 дә — 308, 1926 да — 323, 1938 дә — 350, 1949 да — 328, 1958 дә — 241, 1970 тә — 273, 1979 да — 241, 1989 да — 143, 2002 дә — 144 кеше.

**ЯҢА́ БАУЛЫ́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 15 *км* көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 104 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Баулы волостенда, 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1926 да — 277, 1938 дә — 223, 1949 да — 255, 1958 дә — 245, 1970 тә — 162, 1979 да — 121, 1989 да — 61, 2002 дә — 66 кеше.

**ЯҢА́ БӘЗӘКӘ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 45 *км* көньяк-көнбатыштарак, Уса елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 97 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1884–85 тә Иске Бәзәкә һәм Тәкәш авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакла-

рында Починок Новоусовский, Крутовражский исемнәре б-н билгеле. Халкы типтәр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, урманчылык, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1907 дә ачыла), мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 301,0 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязендә, 1921 дән ТАССРның — Әгерже, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерже, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерже р-нында. Халык саны: 1887 дә — 85, 1897 дә — 231, 1920 дә — 166, 1926 да — 181, 1938 дә — 189, 1958 дә — 125, 1970 тә — 202, 1989 да — 128, 2002 дә — 115 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерже төбәге тарихы. К., 2003.

**ЯҢА́ БӘРӘСКӘ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Төшем елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 40 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 18–19 йөзләрдә нигез салына. Беренче исеме Уссюль. 1860 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 242,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 да — Краснококшайск) өязе Күлле Киме волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 117, 1897 дә — 192, 1908 дә — 242, 1920 дә — 211, 1926 да — 242, 1938 дә — 259, 1949 да — 182, 1958 дә — 162, 1970 тә — 140, 1979 да — 94, 1989 да — 64, 2002 дә — 58 кеше.

**ЯҢА́ БИКЛӘ́Н** посёлогы, Чаллы шәһәре составында, Чаллы шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнбатыштарак, Әгерже–Акбаш тимер юлы буенда. 2005 елда 3483 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 51,3%, руслар — 33,2%) яши. Халыкның төп шөгыле — кырчылык, яшелчәчелек; сельхозхимия пр-тиесе, төзелеш, тимер юл транспорты хезмәте күрсәтү. Урта мәктәп. Мәчет. 1954 тә нигез салына, 1956 ның 5 июненнән торак пункт буларак теркәлә. Оешкан көненнән Чаллы (1976 ның 20 апреленнән Тукай) р-нында, 1980 елларда Чаллы шәһәре хакимияте карамагында. Халык саны: 1958 дә — 148, 1970 тә — 378, 1989 да — 3070 кеше.

**ЯҢА́ БОЛГА́Р** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 21 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычыннан 5 *км* читтә. 2010 елда 70 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Зөя кантоны Ташкабак волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 187, 1938 дә — 157, 1949 да — 140, 1958 дә — 145, 1970 тә — 119, 1979 да — 112, 1989 да — 88, 2002 дә — 87 кеше.

**ЯҢА́ БУА́** (Кыр Буасы) авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 34 *км* көньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 129 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1646 дан билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Б.да Изге Гурий бораддәрлеге мәктәбе (1902 дә ачыла), ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 301,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Тояба волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1921-22 дә Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 21 ир-ат; 1859 да — 84, 1897 дә — 185, 1908 дә — 247, 1920 дә — 197, 1926 да — 166, 1938 дә — 218, 1949 да — 193, 1958 дә — 179, 1970 тә — 160, 1979 да — 156, 1989 да — 130, 2002 дә — 145 кеше.

**ЯҢА́ БҮЛӘ́К** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 38 *км* көньяктарак, Инеш елгасы (Игәнәнең сул кушылдыгы) бассейнында. 2010 елда 307 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1931 дә нигез салына. Оешкан көненнән — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1949 да — 245, 1958 дә — 237, 1970 тә — 287, 1979 да — 234, 1989 да — 283, 2002 дә — 298 кеше. Я.Б.тә И.Г.*Шакиров* туган.

**ЯҢА́ БҮСЕРӘ́К** (Кече Бүсерек) авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 31 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бүсерәк елгасы буенда. 2010 елда 35 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1774 тә Иске Бүсерәк авылыннан чыгучылар нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Беленкова исеме б-н мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чабата үрү һәм мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 250 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Спас волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дә Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 февраленнән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 116, 1913 тә — 192, 1920 дә — 247, 1926 да — 180, 1938 дә — 192, 1949 да — 203, 1958 дә — 131, 1970 тә — 288, 1979 да — 70, 1989 да — 41, 2002 дә — 37 кеше.

**«ЯҢА́ ВАКЫ́Т»**, көндәлек иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1917 елның 1 ноябреннән 1918 нең 22 мартына (башка мәгълүматлар буенча, 30 октябрьгә) кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 105 саны чыга. Нашире — «З.Дәминов һәм М.Галәветдинов сәүдә йорты», мөхәррирләре — Ф.*Кәрими*, Ш.*Камал*. Газета милли мохтарият идеясен пропагандалый, Учредительләр җыены чакырылышына, демократик ирек һәм тигез хокуклылык лозунгларына теләктәшлек күрсәтә. Редакция большевиклар һәм эсерлар эшчәнлеген тәнкыйди бәяли. «Я.в.» битләрендә 1918 нең апрелендә булган Самара эшчеләре һәм крәстияннәре съезды барышы һәм нәтиҗәләре, Оренбург шәһәр думасына сайлаулар яктыртыла. Газета «Уфа хәбәрләре», «Безнең фикер», «Мамадыш таңнары», «Яңа хәят» һ.б. татар вакытлы матбугатында чыккан материалларга, ш.у. яңа китапларга күзәтү бирә. Матбугат турындагы Декрет нигезендә ябыла (1918).

**ЯҢА́ ВАРВА́РИНКА** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 73 *км* төньяк-көнбатыштарак, Вятка елгасы (Чишмәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 6 кеше (руслар) яши. 1905 тә Украинадан күчеп кайтучылар нигез сала. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Варварино волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Шөгер, 1959 ның 12 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1920 дә — 428, 1926 да — 496, 1938 дә — 425, 1949 да — 356, 1958 дә — 234, 1970 тә — 237, 1979 да — 58, 1989 да — 19, 2002 дә — 7 кеше.

**«ЯҢА́ ГАСЫ́Р» ТЕЛЕРАДИОКОМПА́НИЯСЕ** (ТНВ), 2001 елның 17 маенда «ТНВ» ААҖ буларак теркәлә. «Татарстан — Яңа гасыр» телеканалын, «Яңа гасыр», «Love-радио Казань» радиостанцияләрен һәм «Татарстан дулкынында» («На волне Татарстана») атналык г-тасын берләштерә. «Татарстан — Яңа гасыр» телеканалы үз эшен 2002 нең 26 августында башлый. Тәүлегенә 22 сәг. татар һәм рус телләрендә тапшырулар алып бара. Хәбәрчелек пунктлары Мәскәү, Екатеринбург, Ульянов, Ижевск, Әлмәттә бар. Иярченнәр аша сигнал Россия терр-ясенә, Европа һәм Азиянең шактый өлешенә, БДБ илләренә тарала. Татарстанның бөтен терр-ясе ышанычлы кабул итү зонасында; телеканал тапшыруларын Башкортстан, Чуаш, Удмурт респ-каларында, Әстерхан, Мәскәү, Новосибирск, Оренбург, Самара, Свердловск, Төмән өлкәләрендә, Краснодар һәм Красноярск төбәкләрендә, Казакъстанда, Финляндия, Төркия, Чехия, Кытайда, Балтыйк буе илләрендә карыйлар. ТНВ сайтында (www.tnv.ru) online-трансляция гамәлгә ашырыла. Программалар Татарстанда, аның чикләрендә яшәүче татарларның милли-мәдәни үзаңын күтәрүгә, татар диаспорасы вәкилләрен бергә туплауга, Россия һәм Евразия медиа киңлегендә Татарстанны уңай яктан

күрсәтүгә юнәлдерелә. Телеканал тамашачыларга телепрограммаларның тулы спектрын, ш.и. 40 тан артык үз программа һәм тапшырулары циклын тәкъдим итә. «Яңа гасыр» (Казан) радиосы Татарстан терр-ядә 91,5 FM ешлыгында татар телендә эшли. Санлы тапшыру Россия буйлап, ш.у. Белоруссиядә, Украина, Финляндия, Румыния, Болгариядә, Балтыйк буе илләрендә гамәлгә ашырыла; кабул итү «НТВ-плюс» челтәре комплексы ярдәмендә алып барыла. Тапшырулар тәүлек буе бара, Казан һәм ТР хәбәрләренә, заманча татар музыкасына өстенлек бирә.

Ген. директоры — И.Ю.*Әминов* (2001 дән).

**«ЯҢА́ ДӨНЬЯ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Самара губерна ком-ты татар-башкорт бюросы органы. «*Кызыл дөнья*» г-тасы дәвамчысы. 1924–25 елларда Самара шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Самара губернасындагы сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышны, төбәктәге татар халкының хәлен яктырта.

**ЯҢА́ ДУВА́Н** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 14 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2010 елда 92 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларда халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, такта яру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 645,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 301, 1897 дә — 352, 1913 тә — 396, 1920 дә — 419, 1926 да — 420, 1938 дә — 379, 1949 да — 318, 1958 дә — 216, 1970 тә — 431, 1979 да — 427, 1989 да — 120, 2002 дә — 98 кеше.

**ЯҢА́ ДУМА́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 7 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кармәт елгасы буенда. 2010 елда 469 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1748 дән билгеле. 1860 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Д.да 2 мәчет, тегермән, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1952 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Мукшы волостенда. 1920 дән ТАССРның — Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 97 ир-ат; 1859 да — 884, 1897 дә — 1550, 1908 дә — 1737, 1920 дә — 1924, 1926 да — 1222, 1938 дә — 1051, 1949 да — 974, 1958 дә — 1044, 1970 тә — 957, 1979 да — 801, 1989 да — 477, 2002 дә — 452 кеше.

**ЯҢА́ ЕЛХО́ВО** (Яңа Елховой) авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 70 *км* төньяк-көнбатыштарак, Вятка елгасы (Чишмәнең уң кушылдыгы) бассейнында. 2010 елда 69 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1895 тә Иске Елхово авылыннан күченүчеләр нигез сала. Халкы игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1057 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Варварино волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 10 октябреннән — Лениногорск р-нында. Халык саны: 1920 дә — 354, 1926 да — 349, 1938 дә — 443, 1949 да — 473, 1958 дә — 347, 1970 тә — 262, 1979 да — 141, 1989 да — 71, 2002 дә — 66 кеше.

**ЯҢА́ ЕЛХОВО́Й НЕФТЬ ЧЫГАНАГЫ́**, Акташ-Яңа Елховой чыганагы, запаслары буенча ТРда икенче урында тора. Бөгелмә шәһәреннән 60 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. Татар гөмбәзенең көнбатыш сөзәклегенә туры килә. 1951 елда ачыла, 1961 дән нефть чыгарыла. Сәнәгый катламнар — 900 дән 1500 *м* га кадәр тирәнлектә ятучы югары девон (Пашия һәм Кын горизонтлары), түбән һәм урта карбон (Турне, Башкорт, һәм Мәскәү яруслары) комташлары һәм алевролитлары. Токым-коллекторлар — 13–25% күзәнәклелек, 97–2000 мкм<+>2 үткәрүчәнлек б-н күзәнәкле һәм күзәнәкле-ярыклы типта. Коллектор катламнарның калынлыгы 1–53 *м*. Ятмалар гөмбәзсыман катлам, структуралы литологик һәм массив тибында, биеклеге 140 *м* га кадәр. Түбән катламда башлангыч катлам басымы 17,9 *МПа*, катлам темп-расы 36–42 °С. Нефть тыгызлыгы 862–924 *кг/м*$^3$, 20 °С та үзлелеге 14,8–69,3 *МПа*, күкерт 1,2–3,1%, парафин күләме 1,9–4,7%, газ факторы 9,8–13,4 *м*$^3$/*т*. Чыганак контур тирәли су кудыру ысулы б-н эшкәртелә. Суырту алымы б-н чыгарыла. Якынча 270 млн. *т*. нефть чыгарылган (2005). Нефтьнең иң күп еллык чыгышы 12,2 млн. *т*. (1974). Нефть бирүчәнлек коэф.ы 0,293.

*Л.В.Просвиркина.*

**ЯҢА́ ЕЛХОВО́Й ҮТӘ ТИРӘ́Н СКВА́ЖИНА** № 20009, ТРда бораулаган иң тирән скважина (5881 *м*). Әлмәт шәһәреннән көнбатыштарак урнашкан. 1988 елда кристаллик нигезнең геол. төзелешен өйрәнү, тирәндәге токымнарның коллектор үзлекләрен бәяләү, углеводород, су-тоз эремәләренең тупланышын ачыклау һәм тикшерү, югары минеральләшкән кайнар, ш.и. йод-бромлы, гелийлы, углеводородлы суларны һ.б. файдалы казылмаларны сәнәгый файдалану мөмкинлеген билгеләү максаты б-н бораулау эшләре башлана. Кристаллик нигез 1803 *м* тирәнлектә ачыла, архей яшендәге сланец һәм гнейслардан гыйбарәт, алар ТР терр-ясендә иң борынгы токымнар (3109+97 млн. ел) булып тора. Тирәнлек арту б-н токымнарның чатнау һәм күзәнәклелеге, нефть рәтендәге углеводородларның күләм концентрациясе; темп-ра (125 °С ка һәм артыграк); җылылык агымының ике тапкыр арта (65 *мВт/м*$^2$) баруы ачыклана. Калынлыгы берничә дистә *м* га кадәр булган 60 файдалы коллектор катламнары ачыклана. 3215 *м* тирәнлектә азот, 3840 *м* да — водород, 4000 *м* да — битум, 4385 *м* да — гелий, 5350 *м* да — бутан (5% ка кадәр), 5386 *м* да графит (5% ка кадәр) һ.б.ның күләме арта.

*Әд.:* Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоносности. К., 1996; Верхоланцев А.П., Гвоздь С.М. Наша скважина глубиной в 3 миллиарда лет... // Георесурсы. 2002. № 4.

**ЯҢА́ ҖИРЕКЛЕ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаллы — Зәй автомобиль юлы буенда. 2010 елда 92 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1910 да нигез салына. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән Тукай) р-нында. Халык саны: 1920 дә — 333, 1926 да — 291, 1938 дә — 276, 1949 да — 459, 1958 дә — 351, 1970 тә — 132, 1979 да — 93, 1989 да — 42, 2002 дә — 46 кеше.

**ЯҢА́ ҖИЯ́Ш** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 19 *км* көньяк-көнбатыштарак, Биҗады елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 168 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1732 дән билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, төрле кәсепләр б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Я.Ж.тә мәчет (1884 тә төзелә) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 758 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1816 да — 40, 1834 тә — 49 ир-ат; 1859 да — 216, 1870 тә — 135, 1884 тә — 316, 1906 да — 389, 1913 тә — 473, 1920 дә — 418, 1938 дә — 313, 1949 да — 278, 1958 дә — 281, 1970 тә — 298, 1979 да — 267, 1989 да — 190, 2002 дә — 148 кеше.

**ЯҢА́ ҖӨЛБИ́** авылы, Әтнә р-нында, Зур Әтнә авылыннан 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кызылсу елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 94 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Көек, Мәрҗан исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу һәм он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1289,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 августыннан — Ту-

кай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 130 ир-ат; 1859 да — 688, 1897 дә — 849, 1908 дә — 848, 1920 дә — 890, 1938 дә — 901, 1949 да — 432, 1958 дә — 424, 1970 тә — 205, 1989 да — 143, 2002 дә — 112 кеше.

**ЯҢА́ ҖӨРИ́**(Карачтау) авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 6 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 24 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1680 нән билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Җ.дә мәчет (1896 да төзелә), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 526,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 30 ир-ат; 1859 да — 163, 1897 дә — 342, 1908 дә — 354, 1920 дә — 353, 1926 да — 353, 1938 дә — 380, 1949 да — 288, 1958 дә — 257, 1970 тә — 220, 1979 да — 154, 1989 да — 65, 2002 дә — 49 кеше.

**ЯҢА́ ЗАДУ́Р** авылы, Чүпрәле р-нында, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. Иске Чүпрәле авылыннан 6 *км* көнчыгыштарак. 2010 елда 49 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 18 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашман хезмәтен үти, игенчелек, терлек асрау, киез итек-киез һәм итек тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, рус-татар мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 868,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Чүпрәле волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 426, 1897 дә — 492, 1913 тә — 860, 1920 дә — 715, 1926 да — 649, 1938 дә — 698, 1949 да — 517, 1958 дә — 405, 1970 тә — 260, 1979 да — 185, 1989 да — 105, 2002 дә — 73 кеше.

**ЯҢА́ ЗАРЕ́ЧЕНСКИЙ** посёлогы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кандыз елгасы буенда. 2010 елда 647 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар 66%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Май з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, дәвалау амбулаториясе. 1910 елларда Лубаш посёлогы буларак нигез салына, 1931 дән 204 нче совхоз посёлогы (соңрак «Баулы»), 1993 тән хәзерге исемендә. Оешкан көненнән Самара губернасының Самара өязе Поповка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1920 дә — 142, 1926 да — 181, 1938 дә — 341, 1958 дә — 1421, 1970 тә — 901, 1979 да — 768, 1989 да — 717, 2002 дә — 655 кеше.

**ЯҢА́ ИБРА́Й** (Чәтрән) авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 25 *км* көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 1452 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, кошчылык; нефть чыгару. М.И.Абдрахманов исем. гимназия, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет (элекке 2 нче җамигъ мәчет; 1909 да төзелә, 1990 да үзгәртеп корыла; архит-ра истәлеге). 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 мәчет, 3 мәктәп, 2 су һәм 2 җил тегермәне, 6 ярма яргыч, тимерче алачыгы, 10 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4337 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1935 нең 10 февраленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 204 ир-ат; 1859 да — 3051, 1897 дә — 2924, 1908 дә — 3495, 1920 дә — 3327, 1926 да — 2688, 1938 дә — 2760, 1949 да — 2486, 1958 дә — 2499, 1970 тә — 2931, 1979 да — 2484, 1989 да — 1653, 2002 дә — 1532 кеше.

**ЯҢА́ ИВАНА́ЕВО** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чөкәнеш елгасы буенда. 2010 елда 198 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Новопоселённая Иванаева исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2036 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 96 ир-ат; 1859 да — 582, 1897 дә — 682, 1908 дә — 945, 1920 дә — 1070, 1926 да — 915, 1938 дә — 712, 1949 да — 503, 1958 дә — 412, 1970 тә — 410, 1979 да — 304, 1989 да — 234, 2002 дә — 243 кеше.

**ЯҢА́ ИГЛА́Й** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 8 *км* көнчыгыштарак, Кондырча елгасы буенда. 2010 елда 554 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1835 елда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Мәләкәс өязе Шламка волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантоны Иске Чаллы волостенда. 1930 ның 10 августыннан Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1926 да — 813, 1938 дә — 963, 1949 да — 824, 1958 дә — 794, 1970 тә — 995, 1979 да — 793, 1989 да — 948, 2002 дә — 645 кеше.

**ЯҢ́А ИЕРУСАЛИ́М**, к. *Воскресение монастыре*.

**ЯҢ́А ИКЪТИСАДИ́ СӘЯСӘ́Т** (нэп), Совет дәүләтенең илнең Беренче бөтендөнья, Гражданнар сугышлары (1914–20) елларында җимерек хәлгә килгән халык хуҗалыгын торгызу өчен базар мөнәсәбәтләрен һәм эшмәкәрлек башлангычын файдалануга нигезләнеп алып барылган сәясәте. 1921 елның мартында РКП(б)ның 10 съездында кабул ителә, 1918–20 еллардагы Гражданнар сугышы чорының *«хәрби коммунизм»* сәясәтенә алмашка килә һәм «яңа» сәясәт исемен ала. В.И.Ленинның 1921–22 елларда РКП(б)ның 10 нчы һәм 11 нче съездларында, 10 нчы конференциясендә, Коминтернның 3 нче һәм 4 нче конгрессларында, Советларның 9 нчы Бөтенроссия съездында ясаган докладлары һәм чыгышларында, ш.у. аның күп кенә хезмәтләрендә («Азык-төлек салымы турында» — «О продовольственном налоге», «Алтынның хәзерге һәм социализмның тулысынча җиңүеннән соңгы әһәмияте» — «Значение золота теперь и после полной победы социализма» һ.б.) нэп фәнни һәм иҗтимагый-сәяси яктан нигезләнә. Нэпның төп эчтәлеге — *продразвёрстканы продналог* б-н алыштыру, базар (товар-акча) мөнәсәбәтләрен торгызу, төрле милек формалары гамәлдә булу, яллы хезмәт һәм арендаланган җитештерү чаралары, хуҗалык исәбе, матди кызыксындыру чараларының төрле ысуллары кулланылу.

Нэп продразвёрстканы продналог б-н алыштырудан башлана (Бөтенроссия ҮБКның 1921 ел 21 март Декреты), бу крәстияннәргә җитештерелгән продукциянең үзләреннән арткан өлешен сатарга мөмкинчелек бирә һәм а.х. үсешенә юл ача. Ләкин Татарстанда 1921–22 дәге корылык (к. *Ачлык* (1921–22 еллар)) һәм 1922–23 тә иген уңмау (к. *Ачлык*) авылның тиз арада нэпка күчүенә комачаулык итә. Аграр секторда нэпка күчү баштарак тулы көченә бармый, 1920 еллар уртасында аның төп принципларын тормышка ашыру көч ала. Моңа 1925 нең язында хөкүмәтнең крәстияннәргә карата ясалган кайбер ташламалары этәргеч бирә: ашлыкны дәүләт тарафыннан билгеләнгән тотрыклы бәяләрдән сатуда катгыйлык кими, дәүләт салымы кимәтелә; җирне чикле вакытка арендага бирү срогы озайтыла; а.х.нда элек урып-җыю чоры б-н чикләнгән яллы хезмәттән файдалану законлаштырыла; сатуга, җитештерү чараларын арендалауга, эшче көчләр яллауга кагылышлы төрле адм. тыюлар бетерелә һәм чикләүләр алына. Акча әйләнешендә дәүләт көйләвен тормышка ашыру өчен 1921 нең 4 октябрендә — РСФСР Дәүләт банкы, шул ук елның декабрендә Дәүләт банкының Казан өлкә конторасы (6 кон-

тон ф-лын үз эченә ала) оештырыла (к. *Милли банк*), аның капиталы респ-ка тулай балансының 66% ын тәшкил итә; төп бурычы сәнәгатьне, а.х.н һәм сәүдәне үстерүгә булышлык итү була. 1922 нең ахырында товар-акча әйләнешенә «совзнак»лар урынына яңа акча — червонецлар кертелә (1924 нең гыйнварына респ-кадагы барлык акча массасының 79,9% ы). 1922–23 тә Татарстанда коммерция банклары һәм аларның ф-лары: Үзара кредит җәмгыяте, Сәүдә-сәнәгать банкының (Промбанк) Татарстан респ-ка конторасы, Татарстан коммерция банкы (Татбанк), А.х. банкының (Сельхозбанк) Татарстан респ-ка конторасы, Казан а.х. кредит җәмгыяте, Бөтенроссия кооперация банкының (Всекобанк) Казан бүлекчәсе ачыла. Банк учреждениеләре системасы А.х. банкының җирле конторасы җитәкчелегендәге авыл кредит кооперациясе (кредит һәм ссуда-саклык җәмгыятьләре) хисабына киңәя. 1925–26 да банкларның сәүдә өлкәсенә гомуми кредит күләме 53387,7 мең сум тәшкил итә, шуның 26937,9 мең сумы (50,5%) дәүләт өлешенә, 18094,9 мең сумы (33,9%) кооперациягә, 8350,5 мең сумы (15,6%) хосусый өлешкә туры килә. Дәүләт банкы респ-ка халык хуҗалыгын кредит б-н тәэмин итүдә беренче урынны били (аның артыннан Промбанк, Татбанк, Всекобанк һәм Сельхозбанк килә).

1922–23 тәге акча реформасыннан соң, а.х.ндагы натуралата салым акчалата салым б-н алыштырыла, бу шәһәр б-н авыл арасында товар-акча мөнәсәбәтләренең киңәюенә булышлык итә. 1923 тә Татарстанда а.х. салымының 57,5% ы акчалата түләнә. А.х., кәсепчелек, керем салымнары, гадәттә, сыйнфый характерда була. Дәүләт директивалары нигезендә керем һәм кәсепчелек салымнары нормаларына ел саен диярлек арту юнәлешендә үзгәрешләр кертелә. Күтәрә алмаслык салымнар салыну сәбәпле банкротлыкка чыгу, килешүләр өзелү очраклары торган саен ешая, нәтиҗәдә сәүдә-сәнәгать пр-тиеләренең, бигрәк тә хосусый пр-тиеләрнең, саны кимүгә бара. Совет җитәкчелеге, авыл һәм шәһәр җирләрендәге шәхси эшмәкәрләрне зур салымнар б-н кысып, махсус рәвештә икътисадта шәхси капитал элементларының көчсезләнүенә ирешергә омтыла. Иң зур салым нисбәте сәүдә-сәнәгать сыйныфына туры килә (40% тирәсе), крәстияннәргә салым һәр 100 сумнан 2,3 сум исәбеннән салына, халык арасында күпчелекне тәшкил иткән эшчеләр, хезмәткәрләр һәм крәстияннәр, барысын бергә алганда, шәхси эшмәкәрләргә караганда салымны 16 тапкырга кимрәк түлиләр. Шәхси эшмәкәр өчен үзәктән төшерелгән салымнардан бигрәк җирле салымнар (биналарга, ш.и. фатирларга, җирле ихтыяҗларга һ.б.) авырлык тудыра. Дәүләт һәм кооперация сәүдәсе, сәнәгать пр-тиеләренә салым, чиста керем суммасына пропорциональ рәвештә (салымның абс. күләме исәпкә алынмыйча) 8%, җирле бюджетка өстәмә б-н — 10–12% күләмендә салына. А.х. салымы сыйнфый принциптан чыгып алына (аның төп авырлыгы хәлле крәстияннәр өстенә төшә): 1 дисәтинәдән уртача 25 пот уңыш алынганда, ярлы крәстияннәр салымны 1 дисәтинәгә 30 кадак, урта хәллеләр — 3 пот 30 кадак, хәлле хуҗалыклар — 6 пот 5 кадак исәбеннән түли. Кооператив җитештерү ширкәтләренә — 10%, артельләр һәм а.х. коммуналарына 25% күләмендә ташлама ясала. 1926–27 дә гамәлгә кергән яңа салым нигезләмәсе буенча крәстияннәрнең терлекчелек һәм кырчылыктан тыш умартачылык, яшелчәчелек һ.б. керем чыганакларына да салым салына. Керемнәре салым салынмаслык минимумнан артмаган ярлы хуҗалыклар (респ-када андый хуҗалыклар 20% ка җитә) а.х. салымын түләүдән тулысынча азат ителә. 1928 дә крәстияннәргә салым салу турындагы яңа, җирле салым органнарына кулакларга индивидуаль рәвештә, закон б-н каралган нормалардан тыш салым салу хокукы биргән 28 нче маддә гамәлгә кертелә. А.х. машиналарын һәм эш коралларын, сәүдә йортлары һәм складларын, дачалар, конторалар һ.б.ны файдалануга биреп торудан, җирләрне, сәнәгать һәм һөнәрчелек-кустарчылык пр-тиеләрен һ.б.ны арендага бирүдән алынган чиста керем салымы күләмен 100% ка җиткерү планлаштырыла. Әлеге чаралар сәнәгать пр-тиеләрен торгызу һәм реконструкцияләү, а.х.н күтәрү өчен тиз арада капитал туплау зарурлыгы б-н дәлилләнә.

Нэп чорында зур тизлек б-н дәүләт, кооперация сәүдәсе һәм хосусый сәүдә үсә. Сәүдә йортларына, башлыча, моңарчы сәүдә эше б-н шөгыльләнмәгән кешеләр хуҗа була (66%). 1923 тә респ-када 3549 сәүдә йорты булып, шулардан 3345 е — шәхси затлар, 114 е — дәүләт, 90 ы кооперация милке булып исәпләнә, 1925 тә әлеге күрсәткечләр тиңдәшле рәвештә — 14478, 487, 2270 һәм 11721. Бу пр-тиеләрнең шактый зур өлеше икмәк һәм кондитер әйберләре, гастрономия һәм бакалея товарлары сату б-н шөгыльләнә. 1926 да сәүдә йортларының товар әйләнеше 144,8 млн. сум тәшкил итә, шуның 42,1% ы дәүләт сәүдәсе, 28,2% ы кооперация сәүдәсе, 29,7% хосусый сәүдә өлешенә туры килә. Ваклап сатуда хосусый капитал өстенлек итә — ул барлык товар әйләнешенең 87% ын, вак кирәк-яраклар сатуда 99% ын били. 1920 еллардан совет хөкүмәте тарафыннан хосусый пр-тиеләргә адм. һәм икътисади басым башлана. Шуның нәтиҗәсендә Казан шәһәрендә генә 1926 ның маеннан 1927 нең маена кадәр товар әйләнеше 30,3 млн. булган 349 кибет ябыла, бу барлык сәүдә-сәнәгать челтәренең 18,4%, барлык товар әйләнешенең 50,1% ын тәшкил итә. Күмәртәләп сату башлыча дәүләт оешмалары кулында була. 1928 дә хосусый сектор, яшелчә-җиләк-җимеш базарын исәпкә алмаганда, күмәртәләп сатудан читләштерелә. Шәхси эшмәкәрләр күмәртәләп сату өлкәсеннән — 1929 да, ваклап сатудан 1930 да тулысынча кысрыклап чыгарыла.

Базар мөнәсәбәтләре үсешенә товар биржалары эшчәнлеге уңай йогынты ясый. 1921 нең декабрендә Мәскәүдә — Үзәк товар биржасы, 1922 дә Казанда товар биржасы ачыла. Алар актив рәвештә ихтыяҗ — тәкъдим мөнәсәбәтләрен ачыклыйлар, товар алмашын көйлиләр, вексельләр, акцияләр, пайлар б-н бәйле операцияләр башкаралар. 1923 тә Казан биржасы тарафыннан 4,8 млрд. сумлык килешү төзелә, шулардан 28,0% ы — сәнәгать товарларына, 23,4% ы — күн чималына һәм күн эшләнмәләргә, 10,9% ы — тарага, 10,3% ы — текстильгә карый. 1925 нең октябренә 76 оешма һәм хосусый зат (шулардан 44 е — дәүләт, 26 сы — хосусый һәм 6 сы кооперация сәүдә-сәнәгать пр-тиесе) Казан биржасында әгъза булып тора. Тулай товар әйләнеше буенча Казан биржасы СССРда 8 нче урын били. 1924–25 тә Татарстандагы барлык сату әйләнешенең 47,5% ы аның катнашында башкарыла. 1927 дә Казан биржасының эшчәнлеге туктатыла, килешүләрне теркәү ТАССР Эчке эшләр министрлыгы карамагына тапшырыла.

1922–27 дә (Югары ХХСның 1922 ел 31 март карары нигезендә) ярминкәләр киң таралыш ала. 1922 дә Казанның «Ташаяк» ярминкәсе кабаттан эшли башлый (анда башка шәһәрләрнең сәүдә вәкиллекләре дә, җирле вәкиллекләр дә катнаша). Чит шәһәрләрнең эре сәүдә фирмаларыннан «Мосгосторг»ның Көнчыгыш конторасы (мануфактура, парфюмерия, тимер эшләнмәләр), Түбән Новгород губернасының Семёнов шәһәреннән «Корьев һәм Ежов ширкәте», Мәскәүнең «Балалар тәрбиясе» фирмасы һ.б. Казан ярминкәсендә үз сәүдә вәкилләкләрен тота. 1924 тә Татарстанда (Казан, Бөгелмә, Алабуга, Минзәлә,Тәтеш, Чистай) — 197 базар һәм 53 ярминкә, 1925 тә 106 ярминкә (18 шәһәр һәм 88 авыл) һәм 190 базар исәпләнә. 1925 тә Казан ярминкәсенең товар әйләнеше, сугышка кадәрге күрсәткечләрне узып китеп, 5 млн. сумга җитә. 1929 ның 21 ноябрендә ТАССР ҮБК һәм ХКС эшләре идарәсе каршындагы Киңәшмә «Ташаяк» ярминкәсенең эшчәнлеген туктату турында карар кабул итә.

Нэп елларында Татарстанда хуҗалык аппаратын үзгәртеп кору тормышка ашырыла. Хезмәт һәм Оборона советының 1921 ел 12 август «Эре сәнәгатьне торгызу, җитештерүне күтәрү һәм үстерүгә кагылышлы чараларның төп нигезләре» карары б-н респ-када трестлар төзелә. Алар мөһим сәнәгать тармакларының хуҗалык исәбе б-н эшләүче иң эре дәүләт пр-тиеләрен туплаган хуҗалык берләшмәләреннән тора. Пр-тиеләр б-н идарә итү, чимал һәм материаллар әзерләү, продукцияне базарда сату буенча барлык хокуклар трестларга бирелә. Трест, синдикат, кантон берләшмәләре системасы сәнәгатьне базар б-н бәйли. 1922 ел башына ТАССР ХХС карамагында 10 трест (ш.и. «Лесотрест», «Металлотрест», «Пищетрест», «Силикаттрест», «Татваленок», «Татшвейтрест», «Электротрест»), 7 кантон берләшмәсе (Буа, Бөгелмә, Алабуга, Мамадыш, Спас, Чаллы, Чистай) исәпләнә. 74 завод һәм фабрика, ш.и. сәнәгатьнең төрле тармакларына караган пр-тиеләр (ш.и. азык-төлек җитештерү өлкәсендә — 32, тире һәм мех эшкәртүдә — 15, полиграфиядә — 15, агач эшкәртүдә — 8, сабын кайнатуда — 4) трестларга берләшә. Респ-ка ХХС структурасына кергән 19 пр-тие 1922 ел ахырында, башлыча чимал булмау һәм җиһазлар тузу сәбәпле, туктап тора. 1922 дә «Элек-

тротрест»ның 11 электростанциясе эшли башлый, 1 нче яртыеллыкта 1 млн. *кВт·сәг* тән артык электр энергиясе җитештерелә (к. *ГОЭЛРО*). 1920 еллар башында трестлаштырылган сәнәгатьнең күп кенә пр-тиеләре зыянга эшли, 1923–24 тә килгән зыян 2,6 млн. сум тәшкил итә. 1925 тән трестлаштырылган пр-тиеләр файдага эшли башлыйлар, 1925–26 да 3 млн. сумнан артык табыш алына. 1927 дә дәүләт секторы пр-тиеләренең табышы 1 млн. сумга якын була. 1920 еллар уртасында Татарстан сәнәгате тулай продукция күләме буенча сугышка кадәрге күрсәткечләргә якынлаша (91,9%). 1920 елларның 2 нче яртысында респ-када дәүләт секторы пр-тиеләрнең 83% ын берләштерә, эшчеләрнең 96,7% ы, җитештерелгән продукциянең 82,4% ы алар өлешенә туры килә. 1925–26 да сәнәгатьтәге тулай продукция — 68,5 млн. сум, ш.и. трестлаштырылган пр-тиеләр өлеше 30,5 млн. сум тәшкил итә. 1926–27 дә ТАССРның якынча 14,6 мең (30,3%) кеше эшләүче цензлаштырылган сәнәгатендә 75,8 млн. сумнан артык (28%). продукция җитештерелә.

Товар әйләнешен җанландыру һәм халыкның сәнәгать товарларына булган ихтыяҗын канәгатьләндерү максатыннан ХКСның 1921 ел 17 май Декреты б-н ваграк сәнәгать пр-тиеләре элекке хуҗаларына кайтарыла. ХКСның шул ук елның 5 июль Декреты Югары ХХСна вак пр-тиеләр ачу һәм аларны дәүләт һәм кооперация оешмаларына, ш.у. хосусый затларга арендага тапшыру хокукы бирә. РСФСР ҮБК һәм ХКС 7 июльдә эшчеләр саны 20 кешедән артмаган, соңрак — зуррак пр-тиеләр ачарга рөхсәт итәләр. 1922 дә 2,5 меңнән артык вак һәм кустарчылык пр-тиесе исәпләнә, аларның якынча 80% ы хосусый затларга карый. Респ-ка продукциясенең 70% ы кустар пр-тиеләрдә җитештерелә. 118 җитештерү берәмлеге, ш.и. 52 фабрика һәм завод, 66 тегермән арендага бирелә. Арендага тапшырганда (башка шартлар тигез булган очракта) кооперация оешмаларына һәм аларның берләшмәләренә, дәүләт учреждениеләренә өстенлек күрсәтелә: арендага бирелгән барлык пр-тиеләрнең 65% ы дәүләт һәм кооперация оешмаларына, 35% ы хосусый затларга (ш.и. 31% ы — элеккеге хуҗаларына) туры килә. 1923 тә 70 мең кеше эшли торган 4 мең пр-тие хосусый затларга карый, аларның сәүдә әйләнеше барлык товар әйләнешенең 30% ын тәшкил итә. 1923–24 тә кустарь сәнәгать продукциясе эре һәм вак сәнәгатьтә җитештерелгән товарның гомуми тулай күләменең 23% ын, 1925–26 да — 16% ын алып тора. 1920 еллар уртасына вак һәм кустарь сәнәгать өлкәсендә эшләүчеләр 39,2 меңнән артык кеше, ягъни респ-ка халкының гомуми саныннан 1,3% исәпләнә. Техник җиһазланыш ягыннан кустарь җитештерү арттa бара: ТАССР ХХС мәгълүматлары буенча, кустарчылык б-н шөгыльләнүчеләрнең гомуми санынннан нибары 6,7% ы механик җайланмалардан файдалана, 19,7% ының гына аерым эш бинасы була. Кустарьларның күпчелеге үзе һәм гаиләсе яши торган йортта эшли. 1928 дә вак сәнәгатьтә кооператив сектор өлеше 7,9 млн. сум (1,4%), дәүләт секторы — 2,8 млн. сум (0,2%), шәхси сектор — 45,1 млн. сум (96,3%) тәшкил итә. 1926 ел ахырына вак сәнәгатьтәге тулай продукциянең 45,6% ы шәхси эшмәкәрләр тарафыннан җитештерелә. 1925–26 да хосусый капиталның 50% ка якыны күн әйберләр тегү һәм агач эшкәртү, 30% ка якыны киез басу, 25% ка якыны кап сугу өлкәсенә карый. 1924–26 да хосусый пр-тиеләр өлеше 20,2% тан 16,2% ка кадәр кыскара. 1927 дән мамык ф-калары һәм май з-дларын хосусый затларга арендага бирү, ш.у. аларга кагылышлы аренда килешүләрен яңарту тыела. Арендалау мөмкинлеге продукцияне респ-каның Сәүдә халык комис-ты билгеләгән бәяләрдән сату һәм аренда хакын пр-тиенең макс. куәтеннән чыгып түләү шарты үтәлгән очракта гына саклана. Нәтиҗәдә, 1929 елга респ-ка икътисадында хосусый сәнәгать тоткан урынның җитди әһәмияте югала.

Аграр секторда нэп тулы көченә җәелә алмый. Нэп чорында а.х. машиналарын һәм инвентарьларын бүлүнең алардан төп өлеш, аеруча эре машиналар б-н иң элек «социалистик сектор» ны тәэмин итүгә корылган системасы булдырыла һәм камилләштерелә. ҮБК һәм ХКСның 1921 ел 16 август Декреты б-н үз әгъзаларын крәстиян хуҗалыгына кирәкле инвентарь һәм кораллар б-н тәэмин итү һәм алар җитештергән продукцияне кооперация аша сату б-н шөгыльләнүче ширкәтләр а.х. кооперативының иң отышлы төре итеп таныла. 1921–23 тә кооперация кооператив кредит, тәэминат-сату һәм җитештерү кооперациясе бергә берләшкән универсаль система буларак оеша. А.х. кооперациясе СССР ҮБК һәм ХКСның 1924 ел 22 август «Авыл хуҗалыгы кооперациясе турында» карары нигезендә күмәк рәвештә а.х. җитештерүе б-н шөгыльләнү һәм ярдәмче пр-тиеләр эшчәнлеген алып бару; үз әгъзаларын эш кораллары, орлыклар, ашламалар б-н тәэмин итү; а.х.нда җитештерелгән товарны эшкәртү һәм сату; машиналар сатып алу һәм алардан файдалану; үз әгъзаларына ссуда бирү кебек вәкаләтләре күздә тотылып законлаштырыла. Нэп елларында хакимият тарафыннан хосусый секторга минимум, күмәкләштерелгән секторга максимум күләмдә капитал кертү төп таләп итеп куела.

Максаты авыл халкын җитештерү чаралары — терлекләр, эш кораллары һәм а.х. машиналары, селекцияләнгән чәчү материаллары һ.б. б-н тәэмин итү булган «Селькредсоюз» крәстияннәрне а.х. җитештерүе һәм кредит бирү буенча берләштерү б-н шөгыльләнә. «Селькредсоюз»га әгъзалык хокукы б-н 6 кантон һәм 2 район союзы керә. Башлангыч челтәр әгъзалары оешманың барлык әгъзалары санынннан 67% тәшкил итә. А.х. кооперациясе ассортиментының 70% ы крәстиян хуҗалыгы кирәк-яракларыннан, 30% ы сәнәгатьтә һәм шәһәр тормышында кулланылучы әйберләрдән тора. «Селькредсоюз»ның товар әйләнешендә хосусый сәүдә зур роль уйный, барлык товарның 49% ы шул секторга карый. 1927 дә крәстиян хуҗалыкларының күмәкләшүе 19% ка җитә. Кооперациягә тартылган крәстияннәрнең (якынча 100 мең кеше) 95% ы кредит һәм сату-алу ширкәтләре, 5% ы җитештерү кооперативлары (колхозлар, машина ширкәтләре, мелиорация һәм сөтчелек артельләре һ.б.) аша күмәкләштерелә. Җитештерелгән товарның тулай күләменнән кооперация оешмалары аша сату уртача 62% тәшкил итә (дәүләт органнары аша — 27%, хосусый сәүдә аша — 11%). 1928 нең 1 октябренә кооператив берләшмәләрнең гомуми саны 1282 гә җитә, авыл халкының күмәкләшү дәрәҗәсе барлык крәстиян хуҗалыкларына карата 32,8% тәшкил итә. Крәстияннәрне җитештерү чаралары б-н тәэмин итү фәкать а.х. кооперациясе аша тормышка ашырыла.

Җитештерү кооперациясе авыл җирләрендә киң таралыш алмый. 1927 дә 397 күмәк хуҗалык, ш.и. 199 а.х. ширкәте (к. *Җирне бергәләп эшкәртү ширкәте*), 145 а.х.артеле (к. *Колхоз* мәкаләсен), 15 а.х. коммунасы (к. *Авыл хуҗалыгы коммунасы*) һәм 38 посёлок ширкәте исәпләнә. 1928 дә колхоз секторы барлык крәстиян хуҗалыкларының 0,5% ын колачлый. Крәстияннәр арасында а.х. ширкәтләре һәм артельләр аеруча таралыш ала. Колхозларның 81% ы — орлыкчылык, 19% ы терлекчелек юнәлешендә махсуслаша. Респ-ка а.х.нда колхоз секторы әһәмиятле урын биләми, 1928–29 да колхозларга тулай продукциянең 2,8% ы туры килә, аның товарлыклы өлеше 3,1% тәшкил итә.

Эшне хуҗалык исәбе б-н алып баручы совхоз хуҗалыклары (к. *Совхоз* мәкаләсен), зыянга эшләүләре сәбәпле, респ-ка а.х.нда иң тотрыксыз санала һәм һәрдаим дәүләт ярдәменә ихтыяҗ кичерә. 1922 нең мартында дәүләт совхоз системасы үзгәртеп оештырыла. ТАССР ХКСның 1922 ел 13 июнь карары б-н «Совхозтрест» оештырыла, совхозлар дәүләт тәэминатыннан алына һәм хуҗалык исәбенә күчерелә. ТАССРдагы 100 совхозның 13 е трестлаштырыла, 13 е кантон җир бүлекләре һәм ТАССР Игенчелек халык комис-ты карамагында калдырыла, 26 сы төрле оешма һәм учреждениеләргә тапшырыла, калганнары бетерелә. 1923–24 тә «Совхозтрест» карамагында 14 совхоз була. 1926 да «Совхозтрест» ның бурычы 661 мең сум б-н исәпләнә. 1926 да трест совхозлары сөрүлекләрнең 37% ын үз көчләре б-н эшкәртә (1928–29 да — 62% ка кадәр), калган җир биләмәләре крәстияннәргә арендага (32%) һәм уңышлата түләү шарты б-н файдалануга (10%) бирелә. А.х.да 123 совхоз дәүләт секторына карый, алар өлешенә респ-кадагы чәчүлек җирләрнең 0,25% ы туры килә.

Нэп елларында аренда мөнәсәбәтләре — җирне һәм җитештерү чараларын арендага бирү-алу киң җәелә. «Җирдән хезмәтчел файдалану турында» законы буенча теге яки бу сәбәп б-н җирне үзләре эшкәртә алмаган хуҗалыкларга аны тулаем һәм өлешләп арендага бирү рөхсәт ителә. Хезмәт коллективларына да, учреждение, пр-тие, оешма һәм хосусый затларга да арендалауга юл куела. Нэп чорында аренда хакын түләүнең акчалата, натуралата, уңышлата, эшләп түләү формалары һәм ш.у. катнаш төре гамәлдә була. 1923 тә

дәүләт биләмәләре: 2222 дис. сөрүлек җирләр, 3465 дис. болын, 140 балык тоту участогы — барлыгы 5687 дис. җир арендага бирелә. 1927 гә барлык сөрүлекләрнең 0,1% ы арендалана. Тулы булмаган мәгълүматлар буенча, ярлы крәстияннәрнең якынча 800 мең дис. сөрүлек җирләре хәлле крәстияннәр тарафыннан эшкәртелә. 1928 дә арендага бирелгән җир мәйданнары 0,6% тәшкил итә. Шул ук вакытта авыл җирендә җитештерү чараларын арендалау киң таралыш ала. 1925 тә крәстиян хуҗалыкларының 51,5% ы — үз эш кораллары, 42,9% ы — арендаланган, 5,6% ы — катнаш эш кораллары; 54,5% ы — үз эш терлекләре, 44,9% ы — алып торылган, 1,6% ы катнаш эш терлеге б-н тәэмин ителгән була.

Нэп төбәк халык хуҗалыгын тиз арада торгызу мөмкинлеге бирә. 1927 гә а.х.ндагы төп күрсәткечләр 1917 ел дәрәҗәсенә якынлаша (к. *Крәстияннәр* мәкаләсен). Ләкин авыл җиренә нэпның соңарып килүе һәм эзлеклелек б-н алып барылмавы, крәстияннәргә катгый хокукый гарантияләр бирелмәү, әлеге сәясәтнең сыйнфый характерда булуы аның тулысынча тормышка ашырылуына комачаулык итә.

Вак товар җитештерүе шартларында иреkле сәүдәгә рөхсәт бирелү капиталистик элементларның беркадәр җанлануына мөмкинлек ача. Яңа буржуазия (нэпманнар) — сәүдәгәрләр, арендаторлар, эшмәкәрләр, алыпсатарлар, комиссионерлар һ.б.үсә бара. Бер үк вакытта авылның социаль катлауларга аерылу процессы бара: крәстияннәр арасыннан кулак һәм батрак төркемнәре калкып чыга. А.х. буржуазиясе (кулаклар) саны 1922–25 тә 0,7% тан 4,8% ка кадәр үсә (к. *Кулаклар* мәкаләсен). 1927 дә авыл җирендә 23,8 дән артык батрак исәпләнә. 1928 дә Татарстанда 168,6 мең атсыз (32,7%) һәм 118,4 мең сыерсыз (23%) хуҗалык була. 1929 ел башына а.х. инвентаре булмаган крәстиян хуҗалыклары якынча 40%, сабанлылар нибары 45,5% тәшкил итә. Дәүләт нэпманнар һәм авыл буржуазиясенең эшчәнлеген катгый күзәтчелектә тота һәм чикләүләр билгели.

Нэп елларында а.х. базарындагы бәяләр проблемасы — совет хөкүмәте крәстиян җитештергән төп продукт булган икмәк бәясен рентабельле экспорт дәрәҗәсендә тотарлык итеп көйләүне максат итеп куйганлыктан, аеруча икмәк бәяләре проблемасы — халык хуҗалыгы үсешендә аеруча кискен тора. Икмәк хәзерләү башлыча «Хлебопродукт» (49%) һәм «Госбанк» (40%) өлешенә туры килә. Үзәк кооперация оешмалары хәзерләүләрне миним. күләмдә алып бара: «Центросоюз» — 2,6%, «Сельскосоюз» — 1,1%. Шулай ук 15 ләп хосусый икмәк хәзерләү конторасы эшли (иң эреләре — «Товарооборот», «Север», «Приволжское товарищество»). 1926 да дәүләт һәм кооперация оешмаларының хәзерләүләр б-н шөгыльләнүен оештыру концепциясе тамырдан үзгәртелә. Әгәр элек үзара көндәшлек тудыру юлы б-н үз эшләренең нәтиҗәлелеген күтәрә, чыгымнарны киметә барган берничә дәүләт һәм кооперация оешмасының базарга берьюлы чыгуы гадәти хәл саналса, 1926 дан алар арасындагы көндәшлек, бәяләр арту сәбәбе күрсәтелеп, зыянлы дип табыла. Нәтиҗәдә, базарга чыккан дәүләт һәм кооперация оешмаларының саны 5 кә калдырыла. Бер үк вакытта а.х. базарында хосусый хәзерләүчеләрнең сәүдә-эшмәкәрлек эшчәнлеге чикләнә. Боларга параллель рәвештә ТАССР Эчке сәүдә халык комис-ты икмәк, чимал, ит, терлек мае һәм йомырка хәзерләү бәяләренең өске чиген билгели. Хәзерләүчеләргә а.х. продукциясен төп хәзерләүчеләр өчен билгеләнгән чиктән артык бәягә алу тыела. Шулай итеп, а.х. базарында директив тәртиптә базар конъюнктурасы б-н бик аз бәйләнешле тотрыклы бәяләр кертелә. Шуның нәтиҗәсе буларак, тотрыклы дәүләт бәяләре б-н ирекле базар бәяләре арасында торган саен арта баручы аерма — «бәяләр кайчысы» барлыкка килә, бу исә крәстиян хуҗалыгының барлык тармакларына тискәре йогынты ясый. Товар кытлыгы шартларында сәнәгать бәяләрен төшерүгә йөз тоту уңай нәтиҗәләргә китерми, товар кытлыгының көчәюенә һәм дәүләт бәяләре б-н ирекле базар бәяләре арасының ерагаюына китерә. 1926–27 дә сәнәгать товарларына ваклап сату бәяләренең төшерелүе респ-ка җитәкчелеге өчен чагыштырмача уңышлы була, бу адым, элеккегә бәя төшерүләрдән аермалы буларак, базар конъюнктурасын исәпкә алып ясала. Ул җитештерелгән эшләнмәләрнең кулланылыш максаты, сугышка кадәрге базар бәяләренә карата кыйммәтлелек дәрәҗәсе һәм базардагы халәт исәпкә алынып, фәкать кайбер товар төркемнәре өчен генә гамәлгә ашырыла. Бәя киметү кытлык кичерүче тармакларга кагылмый. Ләкин шуларга да карамастан, бәяләргә һәм товар массасын бүлүгә планлы күзәтчелекнең катгыйлыгы көтелгән нәтиҗәне бирми; аның тоташ контроль икътисадның барлык якларын колачлаган халәттә генә яши алуы ачыклана. Бәяләр билгеләүдә директив планлаштыру сәясәте, ахыр чиктә, «икмәк хәзерләү кризисы»на һәм нэпның төп принцибыннан — базар икътисадыннан тайпылуга китерә.

Нэпның базар икътисады нигезләре җимерелүгә ш.у. контрактация дә йогынты ясый. Контрактация гарантияле рәвештә тотрыклы бәядән а.х. продукциясе алу максатында аграр секторга план аша тәэсир итү чарасы булып тора. Ул базарны стихияле рәвештә барлыкка килгән бәяләрдән сакларга тиеш була. Контрактация нигездә ирекле рәвештә уздырылган һәм, башлыча, техник культуралар җитештерүчеләрне колачаган 1925–26 еллардан аермалы буларак, 1928–29 дагы контрактация кампаниясе барлык төп а.х. продуктларына да кагыла. Килешүләр колхозлар, җир эшкәртү җәмгыятьләре, чәчүчелек ширкәтләре б-н аванс тәртибендә, кагыйдә буларак, орлыклар алу максатында ссудалар бирү өчен төзелә. 1927–28 дә контрактация респ-кадагы уҗым басуларының 8,9% ына тарала. 1928 дә, крәстиян хуҗалыклары тарафыннан аларның дәүләткә продукция тапшыру буенча алынган барлык йөкләмәләре үз көчендә калган хәлдә, аларны орлыклар, эш кораллары б-н тәэмин итү һәм аванслау бетерелә. 1929 ның 28 август карарында колхозларга акчалата аванс бирүне кыскарту һәм акрынлап туктату, аның урынына колхоз җитештерүен кредитлау һәм тәэмин итү тәкъдим ителә. Продукция килешүдә каралган күләмдә тапшырылмаган очракта җыелган барлык уңышны яки мөлкәтне конфискацияләүдән алып җинаять җаваплылыгына тартуга кадәр булган адм.-мәхкәмә чаралары күрелә башлый. Бу крәстияннәрне килешү төзүдән тайчануга яки аны үтәүдән баш тартуга, нәтиҗәдә а.х. продукциясе җитештерү күләмнәренең кимүенә китерә. Нэпка күчү чорында зур авырлык б-н торгызылган крәстиян базарының җимерелүе контрактациянең кимчелекле нәтиҗәсе булып тора. Шуның б-н бергә, ул базар мөнәсәбәтләренең мөһим компоненты булган кооперациянең икътисади нигезләрен какшата. Крәстиян хуҗалыкларының базарга булган ихтыяҗын канәгатьләндерү һәм аларның үсешен стимуллаштыру ин-ты булган кооперация дәүләтнең крестьяннардан алар тарафыннан җитештерелгән продукцияне тартып алу коралына әверелә. *Крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү* башланганнан соң, контрактация системасы барлык колхозларга тарала; шул рәвешле колхозлар товарсыз мөнәсәбәтләр системасына тартыла. 1920 еллар ахырында, *индустрияләштерү* һәм крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү барышында, нэп бетүгә йөз тота.

Нэп елларында икътисадта барган процесслар респ-ка җәмгыятенең күп якларына катлаулы һәм каршылыклы йогынты ясый. Авылда крәстияннәрнең социаль катлауларга — эшлекле гражданнар төркеме һәм батракларга аерылуы бара. Тормыш темпларының, сыйфатының кискен үзгәрүе, җәмгыять структурасын үзгәртеп кору, мәнфәгатьләр каршылыгы социаль киеренкелек тудыра һәм гражданнарны яңа социаль шартларда үз урыннарын эзләүгә этәрә. «Уңнар» — татар халкының милли мәнфәгатьләре мөстәкыйльлеге тарафдарлары һәм «суллар» — илдә хакимият вертикален көчәйтү яклылар каршылыгында чагылыш тапкан, аларның респ-кадагы җитәкче вазифалардан читләштерелүенә китергән иҗтимагый-сәяси көрәш активлаша (к. *РКП(б) ҮКның дүртенче киңәшмәсе*, «*Солтангалиевчелек*», «*Унбиш җитәкче хаты*», «*Утыз тугыз җитәкче хаты*»). Милли мәсьәлә кискенләшә. 1927–28 дә директива буенча татар алфавитын латин графикасына — *яңалифкә* күчерү башлана, бу татар җәмгыятендә фикер каршылыклары, сәяси килешмәүчелек килеп чыгуга сәбәп була (к. «*Сиксән икеләр хаты*»). Иҗтимагый фикер көрәше фәлсәфи тәгълиматлар, икътисади һәм социаль доктриналарның киң спектрын хасил итә. Нэп елларында мәгариф һәм милли-агарту учреждениеләре (к. *Культура революциясе*), фәнни оешмалар (к. *Гыйльми үзәк*) һәм төбәкне өйрәнү оешмалары (к. *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте*, *Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы*, *Төбәкчелек белеме*, *Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте*, *Татар мәдәнияте йорты*) зур үсешкә ирешә. Бу елларда сәнгатьтә һәм архит-рада авангардизм һәм конструктивизм идеяләрен алга сөргән агымнар киң тарала

(к. «*Всадник*», «*ТатЛЕФ*», *Конструктивизм*), беренче әдәби иҗат берләшмәләре — «Часовой», «Октябрь» (к. *Әдәби түгәрәкләр һәм оешмалар*) һәм язучылар оешмалары (к. *Татар совет язучылары оешмасы*, *Татар пролетар язучылары ассоциациясе*) барлыкка килә. Вакытлы матбугат аерым үсеш кичерә: төрле басмалар дөнья күрә, газета һәм журналларның тиражы чагыштыргысыз дәрәҗәдә арта. Нэп чорында илдә хөкем сөргән социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси киеренкелек совет җитәкчелегенең доктриналь күрсәтмәләрендәге «бөек борылышка» башлангыч биргән 1923–24 дәге артык җитештерү кризисы һәм 1927–28 дәге икмәк хәзерләү кризисы вакытында аеруча ачык чагылыш таба.

*Әд.:* Габидуллин Х.З. Татарстан за семь лет. К., 1927; Ермолаев В.М., Шараф Г.Ш. Сравнительная характеристика татарского, русского и нацменовского крестьянского хозяйства Татреспублики. К., 1927; Ермолаев В.М., Шараф Г.Ш., Хасанов М.А. Очерки по экономической географии Татреспублики. К., 1931; Климов И.М. Образование и развитие Татарской АССР (1920–1926 гг.). К., 1960; Залялов А.М. Социалистическое преобразование сельского хозяйства в Татарии (1917–1937 гг.). К., 1974; Коломыц О. НЭП в промышленности Татарской республики: Дис. ... К., 1995; Шайдуллин Р.В. Крестьянство Татарстана: Экономический и общественно-политический аспекты (1920–1929 гг.). К., 2004.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ЯҢА́ ИЛТӘ́Н** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 68 *км* көнбатыштарак, Кичү елгасының сул кушылдыгы буенда. 1926 елда Илтән-Бота авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Кузайкино волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. 2001 дә авыллар исемлегеннән сызыла. Халык саны: 1926 да — 134, 1949 да — 137, 1958 дә — 96, 1970 тә — 98, 1979 да — 81, 1989 да — 15 кеше.

**ЯҢА́ ИЛТЕРӘ́К** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 10 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 186 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 76%, руслар — 22%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Токмала исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү, Изге Гурий бордәрлеге мәктәбе (1890 да ачыла), су тегермәне, ярма яргыч, тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2336 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 71 ир-ат; 1859 да — 1439, 1897 дә — 1322, 1908 дә — 1437, 1920 дә — 970, 1926 да — 861, 1938 дә — 677, 1949 да — 549, 1958 дә — 533, 1970 тә — 522, 1979 да — 411, 1989 да — 251, 2002 дә — 231 кеше.

**ЯҢА́ ИМӘ́Н** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 22 *км* көньяк-көнбатыштарак, Камышлы елгасы (Минзәләнең сул кушылдыгы) бассейнында урнашкан. 2010 елда 210 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Кирпеч з-ды. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1880 елларда Иске Имән авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Имән, Яңа Имяково исемнәре б-н дә билгеле. Халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 670,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1902 дә — 348 ир-ат; 1920 дә — 738, 1926 да — 525, 1938 дә — 602, 1949 да — 442, 1958 дә — 379, 1970 тә — 385, 1979 да — 313, 1989 да — 199, 2002 дә — 215 кеше.

**ЯҢА́ ИРКЕНӘ́Ш** посёлогы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 33 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 25 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ит өчен терлек асрау. 1921 елда Иске Иркенәш авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Минзәлә кантоны Калтак (1924 тән Яңа Маҗын) волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1922 дә — 74, 1926 да — 85, 1970 тә — 128, 1979 да — 97, 1989 да — 43, 2002 дә — 43 кеше.

**ЯҢА́ ИСА́КОВО** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 22 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан — Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 74 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 249 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Самара губернасының Бөгелмә өязе Спас волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 193, 1889 да — 112, 1910 да — 220, 1920 дә — 197, 1926 да — 269, 1938 дә — 214, 1949 да — 172, 1958 дә — 106, 1970 тә — 106, 1979 да — 106, 1989 да — 77, 2002 дә — 84 кеше.

**ЯҢА́ ИШЛЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 11 *км* төньяктарак, Карлы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 298 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау.Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз ахырында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә (лашман хезмәтен үтиләр), игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1426,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Яңа Кәкерле волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 548, 1897 дә — 773, 1913 тә — 1007, 1920 дә — 1018, 1938 дә — 1260, 1949 да — 965, 1958 дә — 742, 1970 тә — 714, 1979 да — 501, 1989 да — 342, 2002 дә — 314 кеше.

**ЯҢА́ ИШТИРӘ́К** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 37 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 692 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1760–80 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы типтәр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Я.И.тә мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2381 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спиридоновка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1785 тә — 145 ир-ат; 1859 да — 455, 1889 да — 1120, 1910 да — 1594, 1920 дә — 1660, 1926 да — 1512, 1938 дә — 1342, 1949 да — 1259, 1958 дә — 1056, 1970 тә — 1083, 1979 да — 910, 1989 да — 703, 2002 дә — 703 кеше.

**ЯҢА́ ИЯБА́Ш** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Ия елгасы буенда. 2010 елда 418 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 17 йөзнең 2 нче яртысына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Варангози, Варангуш, Барангуш-Яваш, Карангуш-Яваш исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; 2 мәчет, 3 җил тегермәне, ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1215,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә авыл Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 70 ир-ат; 1859 да — 458, 1897 дә — 842, 1908 дә — 883, 1920 дә — 956, 1926 да — 914, 1938 дә — 853, 1949 да — 633, 1958 дә — 557, 1970 тә — 516, 1979 да — 485, 1989 да — 406, 2002 дә — 421 кеше.

**ЯҢА́ КАДЕРМӘ́Т** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Терпеле елгасы буенда. 2010 елда 23 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. 19 йөзнең 1 нче яртысында Иске Кадермәт авылыннан күченүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 160 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1859 да — 43, 1884 тә — 50, 1897 дә — 48, 1906 да — 58, 1913 тә — 82, 1920 дә — 84, 1926 да — 79, 1938 дә — 113, 1949 да — 91, 1958 дә — 105, 1970 тә — 115, 1979 да — 79, 1989 да — 42, 2002 дә — 34 кеше.

**ЯҢА́ КАДИ́**, к. *Утыз Имән*.

**ЯҢА́ КАЕНСА́Р** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Оча елгасының югары агымы буенда. Халкының төп шөгыле — кырчылык, нәселле терлек асрау. 18 йөз ахырында — 19 йөз башында Иске Каенсар авылыннан күченүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 726,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 207, 1897 дә — 367, 1908 дә — 420, 1920 дә — 450, 1926 да — 461, 1949 да — 476, 1958 дә — 404, 1970 тә — 474, 1979 да — 392, 1989 да — 282, 2002 дә — 245 кеше.

**ЯҢА́ КА́МА АРЪЯГЫ́** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кама елгасы буенда. 2010 елда 38 кеше (руслар, татарлар) яши. Агач эшкәртү з-ды. Китапханә. 1946 да нигез салына, торак пункт буларак 1959 да теркәлә. Оешкан көненнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1970 тә — 468, 1979 да — 305, 1989 да — 159, 2002 дә — 76 кеше.

**ЯҢА́ КАМКА́** (Мәүләшә) авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 12 *км* көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 14 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мәүләшә исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 5 җил тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 629 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Мораса волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1945 нең 3 апреленнән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 80 ир-ат; 1859 да — 555, 1897 дә — 783, 1908 дә — 719, 1920 дә — 798, 1926 да — 482, 1938 дә — 396, 1949 да — 342, 1958 дә — 390, 1970 тә — 228, 1979 да — 129, 1989 да — 61, 2002 дә — 23 кеше. Я.К. да язучы Н.*Дәүли* туган.

**ЯҢА́ КАНУННА́Р ЭШЛӘ́Ү КОМИ́ССИЯСЕ** (1767–69), закон проектларын тикшерү органы. Император Екатерина II нең 1766 ел 14 декабрь манифесты буенча яңа законнар җыелмасын эшләү өчен оештырыла. Комиссия составына дәүләт учреждениеләреннән (Сенат, Синод һ.б.), дворяннар катлавыннан, шәһәрләрдән, крәстияннәрнең, казакларның, утрак тормышлы рус булмаган халыкларның кайбер категорияләреннән депутатлар керә. Депутатлар саны даими булмый (518–580 кеше). Татар халкы исеменнән А.Еникиев (Пенза провинциясе), К.Иштиряков (Пермь провинциясе), А.Сәетов (Казан провинциясе), Я.Арсланов (Вятка провинциясе), Я.Даутов, М.Юсупов (Зөя провинциясе), Б.Идебирдиев (Сембер провинциясе), С.Хәлфин (Казанның татар бистәләре), Р.Алкин (Казан өязе), С.Телмиев (Әстерханның Казан бистәсе), И.Хансәетов (Себер губ.), Я.Мангушев (Алатырь провинциясе), У.Ишмаков (Тамбов провинциясе), В.Юлгушев (Шацк провинциясе), А.Даушев (Исет провинциясе), М.Ибраһимов, А.Максютов (Оренбург губ.), М.Пулатаев (Сәет бистәсе), И.Таиров (Ставрополь провинциясе) эш алып баралар. Депутатларга кайбер өстенлекләр бирелә: тән газапларыннан, җәзалардан һәм үлем җәзасыннан азат булу; аларга нинди дә булса мыскыллау яисә зыян салуда гаепләләр икеләтә җәзага тартыла. Моннан тыш депутатларга бер еллык хезмәт хакы билгеләнә. Депутатларны Я.к.э.к. нә сайлаганда наказлар исемлеге төзелә, алар алга таба комиссия утырышларында укыла. Татар халкы наказларында социаль-икътисади тормышның төрле проблемалары чагылыш таба; мәс., Сембер өязе йомышлы морзалары һәм татарлары үз җирләренең кимүен, «казна хезмәтенең», «җан башыннан салым» түләүнең авырлыгын һ.б.ны күрсәтәләр. Казан татарлары хакимиятләрдән рекрутлыкка чакырулардан, «җан башыннан салым» түләүләрдән, мунчалардан алына торган «оброктан килгән акчалардан» азат итүне; аларга алга таба да каршылыксыз сәүдә б-н шөгыльләнергә рөхсәт бирүне сорыйлар. Татарларның наказларында ш.у. көчләп чукындыруны туктату; аларның дини хисләрен яклауны закон нигезендә тәэмин итү зарурлыгы турында да әйтелә. Татар депутатлары Я.к.э.к. утырышларында фикер алышуларда актив катнашалар, сәүдә, мәхкәмә процессы, дин б-н бәйле хәлләр хакында үз карашларын белдерәләр. Элеккеге татар феодаллары даирәсе вәкилләре социаль статусларын торгызырга омтыла: А.Еникиев үзләренең ата-бабаларын «тумыштан кенәзләр, морзалар һәм йомышлы татарлар» дип белдерә, аларны «гади һәм лаек булмаган ясаклы крәстияннәр һәм башка лаек булмаган татарлар б-н ...» тиңләштермәскә тәкъдим итә. Я.к.э.к. каршында күпсанлы «хосусый комиссияләр» оештырыла, аларда закон проектларын алдан эшләү алып барыла. С.Хәлфин — «Халыкны, игенчелекне, йортлар төзелешен арттыру, торулыклар, кул эшләре, сәнгать һәм һөнәрләр турында» комиссиясенә, А.Еникиев — «җыемнар рәвешен һәм чыгымнар рәвешен карау өчен» әгъза булып сайланалар. Моннан тыш ул 1768 нең 22 ноябрендә император Екатерина II янына керергә рөхсәт ителгән вәкилләр составына сайлап алына. Я.к.э.к. эшчәнлеге уңышсыз тәгәлләнә. 1769 да Екатерина II комиссиянең гомуми җыелышын тарата, хосусый комиссияләр 1773 кә кадәр эшләвен дәвам итә. Татар халкының Я.к.э.к. ндә күрсәтелгән кайбер теләкләре Екатерина II нең татарларның дин тоту иреген тану (1773), аларның каршылыксыз сәүдә итүе (1776), татар морзалары һәм Россия дворяннары хокукларын тигезләү турындагы (1784) Фәрманнарында гәүдәләнә.

Чыг.: Сборник Императорского Русского исторического общества. СПб., 1969. Т. 4; 1871. Т. 8; 1875. Т14; 1881. Т. 32; 1882. Т. 36; 1885. Т. 43; 1889. Т. 68; 1894. Т. 93; 1900. Т. 107; 1903. Т. 115; 1907. Т. 123; 1911. Т. 134; 1914. Т. 144; 1915. Т. 147.

*Әд.:* Т а ш к и н С.Ф. Инородцы Поволжско-Приуральского края и Сибири по материалам Екатерининской законодательной комиссии. Оренбург, 1921; В а л и у л л и н И.Р. Деятельность татарских депутатов в Уложенной комиссии 1767 — 1769 гг. // Проблемы истории, культуры и развития языков народов Татарстана и Волго-Уральского региона. К., 2003. Вып. 2.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ЯҢА́ КАРАЗИРЕ́К** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 26 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Башкортстан Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 213 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Клуб. 1910 елларда Иске Каразиректән күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән Самара губернасының Бөгелмә өязе Чәкән волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1920 дә — 430, 1926 да — 365, 1938 дә — 345, 1949 да — 368, 1958 дә — 336, 1970 тә — 402, 1979 да — 311, 1989 да — 284, 2002 дә — 259 кеше.

**ЯҢА́ КАРАМАЛЫ́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 30 *км* көнчыгыштарак, Калмыя елгасы бассейнында. 2010 елда 166 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Минзәлә кантоны Әмәкәй волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1938 дә — 301, 1949 да — 303, 1958 дә — 324, 1970 тә —

310, 1979 да — 264, 1989 да — 192, 2002 дә — 186 кеше.

**ЯҢА́ КАРМӘ́Т** (Яңа Татар Кармәте) авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 6 *км* көнбатыштарак, Кармәт елгасы буенда. 2010 елда 350 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1748 дән билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1644 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Мукшы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 77 ир-ат; 1859 да — 883, 1897 дә — 1426, 1908 дә — 1713, 1920 дә — 1184, 1926 да — 750, 1938 дә — 792, 1949 да — 706, 1958 дә — 687, 1970 тә — 933, 1979 да — 796, 1989 да — 412, 2002 дә — 373 кеше.

**ЯҢА́ КӘКЕРЛЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 14 *км* төньяктарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш. 2010 елда 437 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөз ахырында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче чирегендә халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1830 елларда удел ведомствосы карамагына күчерелә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә, лашман хезмәтен үти. 20 йөздә 3 мәчет, 3 мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2095 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Сембер губернасының Буа өязе Яңа Кәкерле волосте үзәге була, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1066 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 1019, 1897 дә — 1469, 1913 тә — 2006, 1920 дә — 1961, 1926 да — 2079, 1938 дә — 1803, 1949 да — 1241, 1958 дә — 1238, 1970 тә — 1383, 1979 да — 1003, 1989 да — 561, 2002 дә — 489 кеше.

**ЯҢА́ КӘШЕ́Р** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Урсалы елгасы буенда. 2010 елда 1568 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; икмәк з-ды, а.х. техникасы пр-тиеләре. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1746 га кадәр Иске Кәшер авылыннан күченүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлек асрау, дуга, тугым, чана табаны, чаналар ясау, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1764 елгы мәгълүматларга караганда, болгаткыч калаклы 3 тегермән, 1795 тә — мәчет, 1859 да 2 мәчет була. 20 йөз башында 3 мәчет, 3 мәктәп, 4 су тегермәне, 2 тимерче алачыгы, 5 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4184 дис. тәшкил итә. 1920 еллар тирәсендә дүртенче мәчет ачыла. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Урсалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1746 да — 35, 1762 дә — 45 ир-ат; 1795 тә — 640, 1859 да — 1707, 1889 да — 3140, 1910 да — 3732, 1920 дә — 3683, 1926 да — 807, 1938 дә — 2860, 1949 да — 2372, 1958 дә — 2412, 1970 тә — 2805, 1979 да — 2461, 1989 да — 1702, 2002 дә — 1672 кеше.

**ЯҢА́ КЕНӘ́Р** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 40 *км* төньяктарак, Ашыт елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 2551 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау; агач эшкәртү комб-ты, яшелчә киптерү з-ды, азык-төлек комб-ты, «Кенәр авыл хуҗалыгы техникасы» АҖ. Урта мәктәп, мәктәп-интернат, мәдәният йорты, 2 китапханә. 17 йөздә Иске Кенәрдән күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бигәш, Мәмсә исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында монда волость идарәсе урнаша; 4 мәчет, почта бүлекчәсе, 5 җил тегермәне, 3 тимерче алачыгы, 3 зур һәм 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире (Шенәр Кенәр авылын кертеп) 4122,5 дис. тәшкил итә.1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волосте үзәге була, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл р-ны үзәге (1956 ның 18 июленнән — Тукай), 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 1503, 1897 дә — 2030, 1908 дә — 2428, 1920 дә — 2228, 1926 да — 1027, 1938 дә — 1927, 1949 да — 1824, 1958 дә — 2154, 197 тә — 2440, 1979 да — 2548, 1989 да — 2300, 2002 дә — 2443 кеше.

*Әд.:* Арча төбәге тарихы — История Арского края. К., 1996.

**ЯҢА́ КЕРӘШЕ́Н МӘКТӘПЛӘРЕ́**, Рус православие чиркәвенең Идел һәм Урал буендагы рус булмаган халыклар вәкилләрен (чуаш, керәшен татарлар, мари, удмуртлар) укыту өчен билгеләнгән миссионерлык уку йортлары. Аларның төп максаты — рус булмаганнарның телләрен һәм гадәтләрен белүче православие рухани кадрлары әзерләү. Беренче Я.к.м. Казанда митрополит Тихон (Воинов) тарафыннан 1707 елда ачыла (1709 да, акча булмау сәбәпле, гражданнар хакимиятләре тарафыннан ябыла; 1722 дә кабат ачыла). 1723 тә ул Казан славян-латин мәктәбе б-н берләштерелә, 1732 дә Казан руханилар семинариясе итеп үзгәртелә, анда 1740 еллар ахырына кадәр рус булмаган крәстиян балалары өчен махсус сыйныфлар эшләп килә. 1731 дә миссионер Алексей Раифский Зөя *Успение монастырендa* Я.к.м. ача, 1740 тан ул *Яңа чукындырылганнар конторасы* каршында эшли. 1740 та император Анна Иоановна Фәрманы б-н Казанда, Цивильскида, Царёвококшайскида, Алабугада мәктәпләр ачуга күрсәтмә бирелә. Фәрман үтәлми, 1745 тә император Елизавета Петровна тарафыннан яңартыла. 1750 дә Казанда (Фёдоров монастырендa), Царёвококшайскида, Алабугада (бер елдан янгыннан соң ябыла) мәктәпләр ачыла. 1754 тә епископ Лука (Конашевич) башлангычында барлык мәктәпләр бер Казан Я.к.м.нә берләштерелә, шуның өчен Иске Татар бистәсендә Захария һәм Елизавета чиркәве янында биналар комплексы төзелә. 1785 тә архиепископ Амвросий (Подобедов) Казан Я.к.м.нә реформа уздыра, чынлыкта аны махсус руханилар семинариясе сыйныфларына әверелдерә (1800 дә ябыла).

Казандагы Я.к.м.ндә укучылар саны төрле елларда 150 дән 270 кә кадәр тәшкил итә. Аларга Яңа чукындырылганнар эше конторасы ябылганга кадәр 1764 тә чуаш, керәшен татарлар, мари һәм удмурт балалары рекрут хезмәтенә алмашка мәҗбүри җыела. Я.к.м.ндә укыту процессының нәтиҗәлелеге махсус пед. система юклыктан, укытучылар составының дәрәҗәсе бик түбән шартларда сыйфатлы булмый: укучыларның туган телләре укытылмый, рус телен махсус өйрәнү дә каралмаган; уку славян телендәге чиркәү хезмәте һәм чиркәүдә җырлау өчен кирәкле текстларны механик рәвештә ятлауга кайтып кала. Алексей Раифскийның Зөя Я.к.м.ндә һәм Амвросий (Подобедов) карамагындагы Казан Я.к.м.ндә хәл яхшырак була.

Гомумән, Я.к.м. Идел буе халыклары мәдәниятен үстерүгә һәм аларны христианлаштыруга җитди өлеш кертми. Ел саен 9–10 тәрбияләнүче пономарь һәм дьяк булып, бик сирәк кенә дин әһеле булып китәләр, шул ук вакытта күбесе рус приходларында хезмәт итә, кайберләре озак еллар уку дәвамында ана телләрен онытала.

*Әд.:* Харлампович К.В. Казанские новокрещенские школы (К истории христианизации инородцев Казанской епархии в XVIII в.). К., 1905; Никольский Н.В. Христианство среди чуваш Среднего Поволжья в XVI–XVIII вв.: Ист. очерк. К., 1912. *Е.В.Липаков.*

**«ЯҢА́ КИТА́П» НӘШРИЯТЫ́**, Казанда 1926 елда оешкан кооператив нәшрият. Оештыручылары, пайчылары — Ф.*Бурнаш*, К.*Нәҗми*, М.*Гали*, С.Фәйзуллин, К.*Тинчурин*, С.*Җәлал*, З.*Нуркин*, Ш.Байчура, Л.Гомәров, М.*Бәдәйли*, З.Гыймранов, Ф.Мөхәммәдъяров, К.Халидов, З.Измайлов, Ф.*Әмирхан*, Б.Биккулов, И.Әхтәмов, Г.*Хәбиб*. Ә.*Хәсәни* нәшрият эше белгече буларак чакырыла. Нәшриятның максаты — халыкны «фәнни һәм иҗтимагый белем һәм сәнгатьнең бөтен тармаклары буенча, бигрәк татар телендә, популяр һәм бәясе дә арзан булган әдәбият» б-н тәэмин итү. 1926 да Л.Гремяцкийның «Җирдәге беренче кешеләр» («Первые люди на Земле», Г.Сөләйман тәрҗемәсе) һәм В.Язвицкийның «Кесә уты» («Карманный огонь», Фәйзи тәрҗемәсе) китаплары, 1927 дә 16 китап — М.Горькийның «Макар Чудра» (С.Җәлал тәрҗемәсе), Д.Фредманның «Нәрсә ул мәхәббәт» («Что такое любовь»), табиб Ф.Басыйровның «Рахит» һ.б., татар халык җырларыннан 5 җыентык, Татар дәүләт акад. театры турында Ф.Бурнаш әзерләгән 2 хезмәт дөнья күрә. Окт. рев-циясенең 10 ел-

лыгына татар язучыларының шигырьләре һәм хикәяләре җыентыклары (төзүчеләре Г.Минский, И.Хәйруллин) чыга. 1928 дә басылган китаплар арасында — Дж. Лондонның «Чинаго»(Ф.Әмирхан тәрҗемәсе), татар һәм рус язучылары Г.Гали, Г.Толымбай, П.Романов хикәяләре җыентыклары, Ш.Усмановның «Идел буйлап» хикәяләр җыентыгы, Г.Кутуйның «Балдызкай» комедиясе һ.б. Соңгы басма — «Яңа русча-татарча сүзлек» («Новый русско-татарский словарь») (якынча 32 мең сүз). Нәшрият тарафыннан гомуми тиражы 123 мең данә булган 27 китап басыла. Үз басмаханәсе булмаганлыктан, «Я.к.» Казандагы дәүләт басмаханәләре: Татполиграф, «Татарстан», Луначарский исем. полиграфия мәктәбе каршындагы басмаханәгә заказлар бирә. 1929 да ябыла.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Книги и люди. К., 1985.

**ЯҢА́ КИШЕ́Т** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Симет елгасы буенда. 2010 елда 393 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 җил тегермәне, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2315 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 185 ир-ат; 1859 да — 976, 1897 дә — 1455, 1908 дә — 1461, 1920 дә — 1282, 1926 да — 1136, 1949 да — 580, 1958 дә — 552, 1970 тә — 585, 1979 да — 492, 1989 да — 389, 2002 дә — 426 кеше.

**ЯҢА́ КЛЮЧИ́ЩЕ** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 31 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кесмәс елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. 18 йөз ахырында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1232,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1921–22 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 395, 1897 дә — 631, 1908 дә — 749, 1920 дә — 687, 1926 да — 741, 1938 дә — 528, 1949 да — 398, 1958 дә — 273, 1970 тә — 124, 1979 да — 48, 1989 да — 20, 2002 дә — 5 кеше.

**ЯҢА́ КОКША́Н** посёлогы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 30 *км* төньяктарак, Удмурт Респ-касы б-н чиктәш. 2010 елда 88 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча татарлар 65 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. Завод уч-щесе бинасы (19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге). 1850 еллар тирәсендә эшмәкәр Ушковларның Кокшан з-ды посёлогы буларак нигез салына. Халкы, заводта эшләүдән тыш, игенчелек, терлек асрау, сатуга утын бәйләү (әзерләү), синиль кәсебе б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында уч-ще эшли. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Грахово волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 243, 1887 дә — 469, 1926 да — 791, 1938 дә — 720, 1970 тә — 412, 1979 да — 206, 1989 да — 111, 2002 дә — 92 кеше.

**ЯҢА́ КОМАЗА́Н** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Комазан елгасы буенда. 2010 елда 443 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәчет. 1710–11 еллардан билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөздә мәчет, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1219,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 111 ир-ат; 1859 да — 513, 1897 дә — 856, 1908 дә — 1098, 1920 дә — 1043, 1926 да — 1088, 1938 дә — 1039, 1949 да — 788, 1958 дә — 627, 1970 тә — 780, 1979 да — 688, 1989 да — 503, 2002 дә — 485 кеше.

**ЯҢА́ КОРМА́Ш** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 24 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 423 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау, умартачылык. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 19 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, сарык тиресе иләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1893–94 тә төзелә), мәдрәсә-мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2101, 3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1834 тә — 11, 1859 да — 336, 1870 тә — 404, 1884 тә — 504, 1897 дә — 600, 1906 да — 736, 1913 тә — 838, 1920 дә — 801, 1926 да — 692, 1938 дә — 901, 1949 да — 674, 1958 дә — 573, 1970 тә — 667, 1979 да — 551, 1989 — 439, 2002 дә — 399 кеше.

**ЯҢА́ КОТЫ́Ш** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 26 *км* көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 9 кеше (руслар, мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, тимерче алачыгы, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1643,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Беренче май, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 454, 1897 дә — 593, 1908 дә — 861, 1920 дә — 994, 1926 да — 440, 1949 да — 256, 1958 дә — 258, 1970 тә — 239, 1979 да — 159, 1989 да — 96, 2002 дә — 51 кеше.

**«ЯҢА́ КӨЧ»**, газета; к. *«Кызыл дөнья»*.

**ЯҢА́ КУЖА́К** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Лашчы елгасы буенда. 2010 елда 58 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 435,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Тәтеш өязе Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 57 ир-ат; 1859 да — 214, 1897 дә — 288, 1908 дә — 380, 1920 дә — 333, 1938 дә — 237, 1949 да — 130, 1958 дә — 124, 1970 тә — 134, 1979 да — 106, 1989 да — 72, 2002 дә — 56 кеше.

**ЯҢА́ КУМО́Р** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 31 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мишә елгасының югары агымы (Мишә бассейны) буенда. 2010 елда 156 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, удмуртлар — 76%, татарлар — 23%) яши. Халкының төп шөгыле — ит терлеге асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1873 тә Югары Кумор авылыннан күченүчеләр нигез сала. Халкы игенчелек, терлек асрау, йөн тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 87,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 37, 1897 дә — 78, 1908 дә — 106, 1920 дә — 120, 1926 да — 119, 1938 дә — 163, 1949 да — 153, 1958 дә — 132, 1970 тә — 175, 1979 да — 161, 1989 да — 131, 2002 дә — 158 кеше.

**ЯҢА́ КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнбатыштарак, Юри елгасы буенда. 2010 елда 5 кеше (татарлар) яши. 1730 елларга кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, тер-

лек асрау, чыпта-кап сугу, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп (1830 дан билгеле) эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 704,6 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1811 дә — 100, 1859 да — 169, 1887 дә — 298, 1905 тә — 376, 1920 дә — 492, 1926 да — 474, 1938 дә — 352, 1958 дә — 130, 1970 тә — 91, 1989 да — 22, 2002 дә — 9 кеше.

**ЯҢА́ КЫРЛА́Й** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 22 *км* төньяктарак, Ия елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 535 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Г.Тукай музей-комплексы. Мәчет. 17 йөз ахыры — 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённая Гарь, М.Крылай исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә –



Яңа Кырлай авылы. Мәчет. 1911.

19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, аяк киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 903,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 2 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 21ир-ат; 1859 да — 259, 1897 дә — 580, 1908 дә — 546, 1920 дә — 659, 1926 да — 678, 1938 дә — 810, 1949 да — 692, 1958 дә — 618, 1970 тә — 660, 1979 да — 574, 1989 да — 526, 2002 дә — 525 кеше.

**ЯҢА́ КЫЯЗЛЫ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 23 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 90 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1916 елда нигез салына. Оешкан көненнән Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1940 ның 26 апреленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1920 дә — 262, 1926 да — 239, 1949 да — 349, 1958 дә — 306, 1970 тә — 268, 1979 да — 247, 1989 да — 170, 2002 дә — 119 кеше.

**ЯҢА́ ЛЬЯШ ПҮЧИНКӘСЕ́** авылы, Тәтеш районында, Тәтеш шәһәреннән 32 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бидәңге елгасы буенда. 2010 елда 28 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Мордовская Тайба исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла) була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 608,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Олы Тархан волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 301, 1880 дә — 424, 1913 тә — 507, 1920 дә — 512, 1926 да — 520, 1938 да — 311, 1949 да — 284, 1958 дә — 184, 1970 тә — 146, 1979 да — 99, 1989 да — 45, 2002 дә — 41 кеше.

**ЯҢА́ МА́ВРИНО** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 27 *км* көньяктарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2010 елда 95 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Маврино исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык, олаучылык, чаналар, көпчәкләр ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, тимерче алачыгы эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1636 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 601, 1870 тә — 626, 1897 дә — 863, 1913 тә — 959, 1920 дә — 860, 1926 да — 630, 1938 дә — 737, 1949 да — 581, 1958 дә — 652, 1970 тә — 436, 1979 да — 317, 1989 да — 111, 2002 дә — 88 кеше.

**ЯҢА́ МАҖЫ́Н** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 33 *км* көньяктарак, Ык елгасыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 345 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1740 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Покровский, Сурончаг исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык, тегүчелек, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында анда волость идарәсе, почта станциясе урнаша; Покров чиркәве (1817 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1877 дә ачыла), китапханә, 6 кибет була; җомга базары; кечкенә базар (Изге Троица көнендә, 29 июнь, 1 октябрь) эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3712,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Богодаровка волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1859 да — 609, 1870 тә — 859, 1884 тә — 964, 1897 дә — 1279, 1906 да — 1413, 1913 тә — 1564, 1920 дә — 1503, 1926 да — 1473, 1938 дә — 827, 1949 да — 629, 1958 дә — 609, 1970 тә — 671, 1979 да — 551, 1989 да — 446, 2002 дә — 397 кеше.

**ЯҢА́ МАЛЫКЛЫ́ РАЙОНЫ́**, *Ульянов өлкәсенең* төньяк-көнчыгыш өлешендә, ТР б-н чиктәш урнашкан. 1935 елда оештырыла. Мәйданы — 971,2 *км*². Үзәге — Яңа Малыклы авылы (Ульянов шәһәреннән 125 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 14162 кеше (2017). Татарлар саны: 1989 да — 5933, 2002 дә — 5550, 2010 да — 4433 кеше. Тупланып район үзәгендә, Әбдери, Зирекле Куак, Лабит, Урта Исәнтимер, Иске Исәнтимер, Иске Бесовка, Иске Төгәлбуга, Өчкаен авылларында яшиләр. 20 йөз башында бу торак пунктларда мәчетләр эшли, ш.и. Әбдеридә — 3, Зирәкле Куакта, Лабит, Урта Исәнтимердә — 2 шәр; Әбдеридә «Үрнәк» мәдрәсәсе һәм мәктәп эшли. Хәзерге вакытта Зирәкле Куак, Урта Исәнтимер, А.Ф.Юртов исем. Иске Бесовка, Иске Төгәлбуга авыллары мәктәпләрендә татар теле фән буларак укытыла; татар теле түгәрәкләре оештырыла. Хәзерге вакытта районда Татар милли-мәдәни автономиясе, Урта Исәнтимер авылы мәдәният йорты каршында татар халык театры, «Язгы көйләр» татар җыры коллективы, «Айгөл» балалар фольклор ансамбле эшли. Ел саен Сабан туе бәйрәме уздырыла. Район терр-ясендә — 13, ш.и. Урта Исәнтимердә 4 мәчет эшли. Я.М.р.нда ТАССРның халык артисты Ф.К.*Туишев*, генерал-лейтенант Ә.Н.*Рамазанов*, филол. фән. д-ры М.В.*Гайнетдинов*, тарих фән. д-ры Р.В.*Шәйдуллин*, язучы Л.Х.*Хәмидуллин*, дин һәм сәясәт эшлеклесе Г.Б.*Ашмасов* туган.

**ЯҢА́ МАМО́НИНО** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер-юл станциясеннән 7 *км* төньяктарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 23 кеше (руслар) яши. 1920 гә кадәр нигез салына. Оешкан көненнән Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1920 дә — 58, 1938 дә — 103, 1949 да — 114, 1958 дә — 92, 1970 тә — 74, 1989 да — 26, 2002 дә — 21 кеше.

**ЯҢА́ МӘЛЕ́М** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер-юл станциясеннән 11 *км* көнчыгыштарак, Урман Зәе елгасыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 73 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. Мәчет. 1924 тә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Зәй волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең — 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1926 да — 118, 1938 дә — 182, 1949 — 107 дә, 1958 дә — 181, 1970 тә — 252, 1979 да — 169, 1989 да — 111, 2002 дә — 83 кеше.

**ЯҢА́ МӘЛКӘ́Н** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 14 *км* көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычы буенда. 2010 елда 516 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1738 дән билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 18 йөздә тау з-дларына беркетелә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык, тегүчелек һәм чыпта сугу б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, су тегермәне була. 20 йөз башында миссионерлык мәктәбе (1912–13 уку елында 83 кеше укый) эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3591 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Мәлкән волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 256, 1859 да — 687, 1870 тә — 706, 1884 тә — 900, 1897 дә — 1104, 1906 да — 1201, 1920 дә — 1289, 1926 да — 1169, 1938 дә — 959, 1949 да — 663, 1958 дә — 591, 1970 тә — 658, 1979 да — 945, 1989 да — 704, 2002 дә — 158 кеше.

**ЯҢА́ МӘҢГӘ́Р** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 32 *км* төньяк-көнбатыштарак, Симет елгасы бассейнында урнашкан. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 нчы йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 840,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. 1999 да авыллар исемлегеннән сызыла. Халык саны: 1782 дә — 114 ир-ат; 1859 да — 608, 1897 дә — 680, 1908 дә — 704, 1920 дә — 638, 1926 да — 524, 1938 дә — 472, 1949 да — 265, 1958 да — 159, 1970 — 130, 1979 да — 58, 1989 да — 11кеше.

**ЯҢА́ МӘРТЛЕ́** авылы, Буа р-ны, Буа шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Олы Тилчә елгасы буенда. 2010 елда 238 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ит терлеге асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. 1830 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, аннары удел ведомствосына күчерелә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 171,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 192, 1880 дә — 250, 1897 дә — 345, 1913 тә — 450, 1920 дә — 478, 1926 да — 500, 1938 дә — 507, 1949 да — 350, 1958 дә — 244, 1970 тә — 520, 1979 да — 436, 1989 да — 296, 2002 дә — 261 кеше.

**ЯҢА́ МЕНДЕЛЕ́ЕВ ХИ́МИЯ ЗАВОДЫ́**, к. *«Менделеевазот»*.

**«ЯҢА́ МИЛЛИ́ ЮЛ»**, иҗтимагый-сәяси, фәнни-әдәби журнал. 1928 елның 23 декабреннән 1939 ның октябренә кадәр Берлинда, Варшавада татар телендә айга 2 тапкыр нәшер ителә, барысы 136 саны чыга. 1930 га кадәр «Милли юл» исеме б-н басыла. Гарәп графикасы кулланыла, кайбер язмалар немец, кырым-татар, төрек телләрендә дөнья күрә.




«Яңа милли юл» журналы.

Нашире һәм мөхәррире — Г.*Исхакый* (баштагы 19 санында «К.Русак» тәхәллүсе б-н яза). Газетаны нәшер итүгә Г.Х.*Терегулов* ярдәм итә. Авторлар исәбенә Кытай, Япония, Төркия, Финляндия, Польша, Германия, Румыниядә яшәүче татарлар: Х.Габдүш, С.Гыйффәт, З.Кадыйри, Л.Каран, Р.Мөхәммәдиш, В.Хәким һ.б. керә. Һәр санда халыкара вакыйгаларга күзәтү ясала. Журнал руслаштыруны, СССР халыкларын дин һәм милли ирегеннән мәхрүм итүне кискен тәнкыйтьли. Төрки халыкларның милли азатлык хәрәкәте эшлеклеләренә, татар халкының атаклы вәкилләренә (Й.Акчура, Габдрәшит Ибраһимов, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Ф.Туктаров һ.б.) зур игътибар юнәлтелә. Г.Исхакый публицистикасының төп юнәлеше ирек, татар халкының тарихи истәлекләрен яңарту, тоталитар режим шартларында аның үзсаклануы идеяләреннән гыйбарәт була. Татар әдәбияты һәм теле үсеше мәсьәләләренә, татарларның милли-мәдәни тәңгәллегенә зур урын бирелә. Заманча татар мәктәбенең төп бурычы сыйфатында әдәби телне белгән, киң белемле үсеп килүче буынны әзерләү алга сөрелә.

*Әд.:* Миңнегулов Х. Азатлык көрәшенең мөнбәре // Казан утлары. 1993. № 3.

**ЯҢА́ МИНЗӘЛӘБА́Ш** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 26 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 169 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 1924 тә Иске Минзәләбаш авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Кармалы волостенда. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1926 да — 389, 1938 дә — 469, 1949 да — 409, 1958 дә — 313, 1970 тә — 374, 1979 тә — 267, 1989 да — 72, 2002 дә — 132 кеше.

**ЯҢА́ МИ́НЬКИНО** (Яңа Минкә) авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 13 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зәй елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 122 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 19 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, балыкчылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, 2 җил тегермәне була. 1920 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 536,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарево волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 163, 1913 тә — 278, 1920 дә — 317, 1926 да — 285, 1938 дә — 342, 1949 да — 281, 1958 дә — 236, 1970 тә — 212, 1979 да — 124, 1989 да — 76, 2002 дә — 65 кеше.

**ЯҢА́ МИХА́ЙЛОВКА** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Урсалы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 343 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. Чиркәү. 18 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Рус Шарламасы, Түбән Михайловка исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (дворян Пасмуровларга карый) катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, олаучылык б-н шөгыльләнә, ш.у. тирә-яктагы алпавыт утарларында көнлекче була. 20 йөз башында Знамения Пресвятой Богородицы чиркәве (1890 да төзелә), земство мәктәбе (1879 да ачыла), пар тегермәне, икмәк саклау-сату, 4 бакалея, 1 казна шәраб кибете һәм 1 сыраханә; дүшәмбе көннәрдә базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1048,73 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Кәшер волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1800 дә — 114, 1834 тә — 578, 1859 да — 684, 1870 тә — 810, 1884 тә — 1026, 1897 дә — 1063, 1905 тә — 991, 1913 тә — 947, 1920 дә — 1225, 1926 да — 1000, 1938 дә — 898, 1949 да — 677, 1958 дә —

719, 1970 тә — 497, 1979 да — 299, 1989 — 143, 2002 дә — 261 кеше.

**ЯҢА́ МИЧӘ́Н** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 12 *км* көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы буенда. 2010 елда 322 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, тимерче алачыгы, тегермән, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1636 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 177 ир-ат; 1859 да — 723, 1897 дә — 975, 1908 дә — 1056, 1920 дә — 1086, 1926 да — 995, 1938 дә — 823, 1949 да — 722, 1970 тә — 554, 1979 да — 481, 1989 да — 361, 2002 дә — 361 кеше.

**ЯҢА́ МОРДВА́ КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Спас р-нында (элеккеге Яңа Мордва авылы янында) урнашкан. Я.М.к. истәлекләре 1880 елда Н.Ф.Высоцкий, 1960–70 елларда А.Х.Халиков, 1989 да Е.П.Казаков һ.б. тарафыннан тикшерелә. 7 туктаулыкны (3 се — неолит, 4 се бронза гасыр дәверләренә карый), 2 авыллыкны (*Ананьино культурасы һәм Имәнкискә культурасы*), 12 каберлекне һ.б. археол. истәлекләрне үз эченә ала. Истәлекләрнең күпләп туплануы Идел һәм Каманың күпсанлы елгалары һәм күлләре булган үзәннәрен тоташтырган әлеге төбәктә биол. байлыкларның мул булуы б-н аңлатыла. Җирлек төрлечә хуҗалык иткән (җыючылык, сунарчылык, балыкчылык, терлекчелек, игенчелек) борынгы халыкның яшәеше өчен уңайлы булган. Фән дөньясында төрле әйберләр табылган һәм өсләренә әлгәреге тимер гасырга хас хәнҗәрләр һәм сугыш балталары сурәтләре ясалган каберташлар куелган Ананьино каберлекләре материаллары киң танылган. Хәзерге вакытта Я.М.к. истәлекләре актив рәвештә Куйбышев сусаклагычы сулары тарафыннан җимерелә.

*Әд.:* Ш т у к е н б е р г А.А., В ы с о ц к и й Н.Ф. Материалы для изучения каменного века в Казанской губернии // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1885. Т. 14, вып. 5; Х а л и к о в А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; ш у л у к. Волго-Камье в начале эпохи раннего железа. М., 1977; ш у л у к. Приказанская культура // Свод археол. источников. М., 1980. Вып. 1–24; Археологическая карта Татарской АССР: Западное Закамье. К., 1986.

*Е.П.Казаков.*

**ЯҢА́ МУКШЫ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 14 *км* көньяктарак, Олы сөлчә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 200 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1302 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мукшы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 222 ир-ат; в 1859 да — 445, 1897 дә — 708, 1908 дә — 914, 1920 дә — 866, 1926 да — 723, 1938 дә — 744, 1949 да — 541, 1958 дә — 520, 1970 тә — 504, 1979 да — 351, 1989 да — 225, 2002 дә — 210 кеше.

**ЯҢА́ МУРЗИ́ХА** (Яңа Морзахан) авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 28 *км* көнбатыштарак, Әнҗерә елгасы буенда. 2010 елда 261 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. Халкы 1861 елгы реформага кадәр алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 356 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Казиле волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 164, 1887 дә — 333, 1905 тә — 688, 1920 дә — 727, 1926 да — 863, 1938 дә — 703, 1949 да — 454, 1958 дә — 371, 1970 тә — 352, 1979 да — 397, 1989 да — 371, 2002 дә — 289 кеше.

**ЯҢА́ МУСАБА́Й** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 19 *км* көньяктарак, Мәләкәс елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 161 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 20 йөз башында нигез салына. Оешкан көненнән Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1920 дә — 237, 1926 да — 134, 1938 дә — 315, 1949 да — 434, 1958 дә — 258, 1970 тә — 240, 1979 да — 180, 1989 да — 110, 202 дә — 101 кеше.

**ЯҢА́ НӘДЕ́Р** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 12 *км* көнчыгыштарак, Урсалы елгасы буенда. 2010 елда 1441 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1740 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре, типтәрләр, асабаларга бүленә, игенчелек, терлек асрау, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1764 елгы мәгълүматларга караганда, 2 тегермән, 1795 тә мәчет була. 20 йөз башында анда волость идарәсе урнаша; 3 мәчет, 3 мәктәп, 2 су тегермәне, тимерче алачыгы, 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 5605 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Самара губернасының Бөгелмә өязе Урсалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1746 да — 46 ир-ат; 1763 тә — 165, 1795 тә — 331, 1816 да — 583, 1850 дә — 905, в 1859 — 1089, в 1889 — 1996, в 1897 — 1972, в 1910 — 2473, в 1920 — 2366, 1926 да — 2235, 1938 дә — 2307, 1949 да — 2014, 1958 дә — 1786, 1970 тә — 1686, 1979 да — 1472, 1989 да — 992, 2002 дә — 1127 кеше.

**ЯҢА́ НИКО́ЛЬСКИЙ** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Урман Зәе елгасы буенда. 2010 елда 499 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 68%, татарлар — 26%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Николаевка, Пасмурово исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык, чабата үрү б-н шөгыльләнә, алпавыт Пасмуровлар утарында көнлекче булып эшли. 20 йөз башында Никольский чиркәве



Яңа Никольский авылы. Алпавыт И.К.Пасмуров утары. 20 йөз башы фоторәсеме.

(1830 да төзелә), земство мәктәбе, икмәк саклау-сату кибете, 3 су тегермәне, аракы һәм поташ з-ды, 1 казна шәраб һәм 6 бакалея кибете эшли; һәр сишәмбедә базар; ярминкәләр (9 май һәм 6 декабрьдә) була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 544,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1795 тә — 195, 1859 да — 626, 1870 тә — 862, 1884 тә — 998, 1897 дә — 1199, 1905 тә — 1045, 1913 тә — 1168, 1920 дә — 1284 (Демьянова, Сосновка авылларын, полковник Маслов хуторын кертеп), 1926 да — 927, 1938 дә — 947, 1949 да — 544, 1958 дә — 435, 1970 тә — 280, 1979 да — 259, 1989 да — 351, 2002 дә — 463 кеше. Авылның истәлекле урыны — алпавыт И.К.Пасмуров утары (19 йөз архит-ра истәлеге).

**ЯҢА́ НИКО́ЛЬСКИЙ** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 32 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Оча һәм Өске елгалары (Вятка бассейнында) арасында. 2010 елда 2 кеше (татарлар, руслар) яши. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Халкы дәүләт

крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 245 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 109, 1897 дә — 235, 1908 дә — 339, 1920 дә — 286, 1926 да — 372, 1970 тә — 59, 1979 да — 25, 2002 дә — 7 кеше.

**ЯҢА́ НИКО́ЛЬСКИЙ** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Уфа-Казан автомобиль юлы буенда. 2010 елда 1 кеше (рус) яши. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Питрәч Пүчинкәсе исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 142,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Колай волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 40, 1897 дә — 83, 1908 дә — 122, 1920 дә — 156, 1926 да — 157, 1949 да — 155, 1958 дә — 159, 1970 тә — 73, 1979 да — 48, 1989 да — 13, 2002 дә — 5 кеше.

**ЯҢА́ НИКО́ЛЬСКИЙ** посёлогы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 37 *км* көньяктарак, Наҗар елгасы буенда. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. 1910 елда нигез салына. Беренче исеме Мерзляков хуторы. Оешкан көненнән Вятка губернасының Алабуга өязе Сарсак-Омга волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1920 дә — 41, 1926 да — 31, 1938 дә — 92, 1958 дә — 73, 1970 тә — 39, 1989 да — 8, 2002 дә — 5 кеше.

**ЯҢА́ ОРСК РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1935 елда оештырыла. Мәйданы — 3,4 мең *км*$^2$. Үзәге — Новоорск посёлогы (Оренбург шәһәреннән 365 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 27604 кеше (2017), ш.и. татарлар — 965 кеше (2010). Я.О.р. терр-ясенә татарлар 1740 елларда Оренбург чик буе сызыклары төзелеше б-н бәйле рәвештә килеп урнаша. 1835 тә крәстияннәр хәзерге Татарстан һәм Башкортстан терр-яләреннән Яңа Орск — Троицк чик буена күчерелә. Татарларның күпчелеге Я.О.р. терр-ясенә 20 йөз башында — Столыпинның аграр реформасы барышында килеп утыра. Хәзерге вакытта татарлар, тупланып, район үзәгенең көнбатышында — Кормыш дип аталган өлешендә яшиләр. 1950 елларга кадәр татарлар Ирекле ГЭСы суы астында калган Зубачи (Зубочистка) һәм Таналык авылларында да яшиләр. Зубачи авылыннан күченүчеләр Тукай посёлогын нигезлиләр. Таналык авылында 1930 елларга кадәр мәчет эшли. Совет чорында төрле елларда Зубачи авылында һәм Тукай посёлогында татар мәктәпләре эшли. Хәзерге вакытта Новоорск посёлогының 1 нче һәм Тукай посёлогы мәктәпләрендә татар теле факультатив дәресләрдә өйрәнелә. Новоорскида мәчет эшли. Район китапханәсендә татар әдәбияты бүлеге эшли, аның җирлегендә 2006, 2015 тә М.Җәлил һәм Г.Тукай иҗатына багышланган конференцияләр уздырыла.

*К.С.Гайфуллин.*

**ЯҢА́ ОЧА́** авылы, Мамадыш авылында, Мамадыш шәһәреннән 54 *км* төньяк-көнбатыштарак, Оча елгасы буенда. 2010 елда 112 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 607,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 5 ир-ат; 1859 да — 178, 1897 дә — 258, 1908 дә — 302, 1920 дә — 366, 1926 да — 386, 1949 да — 239, 1958 дә — 253, 1970 тә — 273, 1979 да — 227, 1989 да — 140, 2002 дә — 143 кеше.

**ЯҢА́ ӨҖЕ́М** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Оры елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 62 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире (Өҗем авылын кертеп) 1855 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск өязе (1919 дан — Краснококшайск) Кышлау волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 1177 (Иске Өҗем авылын кертеп), 1897 дә — 519, 1920 дә — 479, 192 да — 443, 1938 дә — 301, 1949 да — 227, 1958 дә — 184, 1970 тә — 137, 1979 да — 108, 1989 да — 81, 2002 дә — 64 кеше.

**ЯҢА́ ПАТРИКЕ́ЕВО** посёлогы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 25 *км* көнчыгыштарак, Зөя елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 12 кеше (руслар) яши. 1927 дә нигез салына. Оешкан көненнән Кайбыч р-нында. 1963 нең 1 гыйнварыннан — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1938 дә — 118, 1949 да — 91, 1958 дә — 60, 1970 тә — 57, 1979 да — 29, 1989 да — 11, 2002 дә — 13 кеше.

**ЯҢА́ ПӘЛЧЕКӘ́Ү** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер-юл станциясеннән 13 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сәрәпәле елгасы буенда. 2010 елда 8 кеше (чуашлар) яши. 20 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Пальчиково-Нератовский хуторы буларак та билгеле. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 98 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1913 тә — 106, 1920 дә — 108, 1926 да — 193, 1938 дә — 153, 1949 да — 132, 1958 дә — 101, 1970 тә — 48, 1979 да — 33, 2002 дә — 4 кеше.

**ЯҢА́ ПОЛЯ́Н**, к. *Полянский*, Апас р-ны.

**ЯҢА́ ПОЛЯ́НА** (Яңа Алан) авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 41 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2010 елда 28 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Лаеш р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 гыйнварыннан — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 204, 1958 дә — 230, 1970 тә — 230, 1979 да — 150, 1989 да — 54, 2002 дә — 40 кеше.

**ЯҢА́ ПОСЁЛОК**, Биектау районында, Биектау тимер юл станциясеннән 10 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казансу елгасыннан 3 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 335 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 59%, татарлар — 33%) яши. 1950 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Биектау р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1958 дә — 146, 1970 тә — 190, 1989 да — 287, 2002 дә — 319 кеше.

**ЯҢА́ ПОСЁЛОК**, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 22 *км* көнчыгыштарак, Шилнә елгасы бассейнында. 2010 елда 1893 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 73%) яши. Халыкның төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе. 1972 дә «*Гигант*» с-зының яңа үзәк утары буларак барлыкка килә. 1999 ның 11 июлендә рәсми рәвештә теркәлә. Оешкан көненнән Чаллы (1976 ның 20 апреленнән Тукай) р-нында. Халык саны: 1979 да — 925, 1989 да — 1635, 2002 дә — 2042 кеше.

**ЯҢА́ РУС МӘМӘТХУҖАСЫ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 5 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1887 дә ачыла), 2 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибе-

те эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 893 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ташёвка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1859 да — 316, 1897 дә — 509, 1906 да — 541, 1908 дә — 541, 1920 дә — 513, 1926 да — 692, 1938 дә — 497, 1949 да — 336, 1958 дә — 258, 1970 тә — 143, 1979 да — 50, 1989 да — 10, 2002 дә — 11 кеше.

**ЯҢА́ САКЛА́У** авылы, Сарман р-нында. Сарман авылыннан 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 22 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау, 1760 — 80 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мансур-саклы, Сөренчәк исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне, тимерче алачыгы, 2 әвен эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 980,21 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Богодаровка волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 243, 1897 дә — 597, 1913 тә — 551, 1920 дә — 697, 1926 да — 475, 1938 дә — 470, 1949 да — 200, 1958 дә — 213, 1970 тә — 200, 1979 да — 134, 1989 да — 53, 2002 дә — 32 кеше.

**ЯҢА́ САЛАВЫ́Ч** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 10 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 231 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — ит өчен терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 644,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Яңгул волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 373, 1884 тә — 399, 1905 тә — 463, 1920 дә — 545, 1926 да — 472, 1938 дә — 494, 1949 да — 407, 1958 дә — 286, 1970 тә — 302, 1979 да — 276, 1989 да — 397, 2002 дә — 222 кеше.

**ЯҢА́ САЛМА́Н** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 13 *км* төньяк-көнбатыштарак, Салман елгасы буенда. 2010 елда 263 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, участок хастаханәсе. Балалар һәм яшүсмерләр өчен «Каенкай» («Берёзка») социаль ятимханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп, 5 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, тимерче алачыгы, 1 мануфактура, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3116,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 205ир-ат; 1859 да — 862, 1908 дә — 1737, 1920 дә — 1653, 1926 да — 719, 1938 дә — 571, 1949 да — 640, 1958 дә — 558, 1970 тә — 502, 1979 да — 459, 1989 да — 314, 2002 дә — 285 кеше.

**ЯҢА́ САРАЙЛЫ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 21 *км* көньяктарак, Шилнә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 124 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 19 йөздә нигез салына. Халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1173, 8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Макарий волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1902 дә — 180 ир-ат; 1920 дә — 488, 1926 да — 292, 1938 дә — 319, 1949 да — 261, 1958 дә — 228, 1970 тә — 231, 1979 да — 156, 1989 да — 106, 2002 дә — 112 кеше.

**ЯҢА́ СӘЕ́Т** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сикия елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 235 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 20 йөз башында нигез салына. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1913 тә — 510, 1920 дә — 729, 1926 да — 570, 1938 дә — 628, 1949 да — 530, 1958 дә — 510, 1970 тә — 554, 1979 да — 442, 1989 да — 301, 2002 дә — 258 кеше.

**ЯҢА́ СӘРДӘ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 51 *км* төньяктарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш. 2010 елда 150 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ит терлеге асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Фәйзуллин Пүчинкәсе исеме б-н дә билгеле. 1860 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (19 йөз ахырында төзелә; архит-ра истәлеге), кытай тукымасы ф-касы, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 691, 6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең — 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 340, 1897 дә — 409, 1908 дә — 459, 1920 дә — 342, 1926 да — 353, 1938 дә — 405, 1949 да — 321, 1958 дә — 331, 1970 тә — 322, 1979 да — 234, 1989 да — 188, 2002 дә — 174 кеше.

**ЯҢА́ СӘРДЕ́К** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 37 *км* төньяк-көнбатыштарак, Киров өлкәсе б-н чиктәш. 2010 елда 233 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, яшелчә үстерү. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1860 еллар тирәсендә Зур Сәрдек авылыннан күченүчеләр нигез сала. Халкы игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 570,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сәрдекбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 8 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1905 тә — 227, 1920 дә — 330, 1926 да — 354, 1938 дә — 404, 1949 да — 371, 1958 дә — 282, 1970 тә — 322, 1979 да — 269, 1989 да — 233, 2002 дә — 259 кеше.

**ЯҢА́ СӘФӘ́Р** посёлогы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 34 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Сарашлы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 78 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 20 йөз башында нигез салына. Халкы игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 1920 гә кадәр посёлок Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1913 тә — 227, 1920 дә — 248, 1926 да — 269, 1938 дә — 93, 1949 да — 72, 1958 дә — 252, 1970 тә — 258, 1979 да — 201, 1989 да — 111, 2002 дә — 94 кеше.

**ЯҢА́ СЕРГИ́ЕВКА РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* үзәк өлешендә урнашкан. 1934 елда оештырыла. Мәйданы — 4,5 мең *км*². Үзәге — Новосергиевка посёлогы (Оренбург шәһәреннән 118 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 34930 кеше (2017). Татарлар саны: 2002 дә — 1900, 2010 да — 2054 кеше. Татарлар Иске Белогор (Искеавыл), Кондызлы (Ново-Кинделька) һәм Мостай авылларында яшиләр. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан 1930 елларга кадәр Иске Белогор авылында мәчет була. 1934–61 дә җидееллык татар мәктәбе эшли, 1961 дә сигезьеллык рус мәктәбе итеп үзгәртелә. Мәктәптә татар теле факультатив дәрестә өйрәнелә (1964 тән). Җирле китапханәдә татар әдәбияты бүлеге эшли. 1994 тә яңа мәчет төзелә. Язучы Л.Х.*Хәмидуллинның*, ТР Сәүдә пр-тиеләре берләшмәсе һәм «Тулпар» Холдинг компаниясе«» ЯАҖ президенты Н.Н.Сөләймановның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Иске Белогор авылы б-н бәйле.

**ЯҢА́ СЕРЁЖКИНО** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 69 *км* көнбатыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш. 2010 елда 361 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1785 кә кадәр Иске Серёжкино авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Смолькино исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, су тегермәне була; һәр сишәмбедә базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Иске Серёжкино авылын кертеп) 2458 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Кармалысы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 8 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1824 тә — 108 ир-ат; 1859 да — 487, 1889 да — 885, 1897 дә — 871, 1910 да — 895, 1920 дә — 895, 1926 да — 797, 1938 дә — 779, 1949 да — 765, 1958 дә — 644, 1970 тә — 766, 1979 да — 647, 1989 да — 384, 2002 дә — 398 кеше.

**ЯҢА́ СИХТЕРМӘ́** посёлогы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 12 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шәпкә елгасы буенда. 2010 елда 68 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Спас кантоны Базарлы Матак волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1926 да — 104, 1938 дә — 103, 1949 да — 99, 1958 дә — 121, 1970 тә — 112, 1979 да — 99, 1989 да — 72, 2002 дә — 79 кеше.

**ЯҢА́ СОЛТА́Н** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Екатерина елгасы буенда. 2010 елда 14 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Солтан исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында башлангыч белем мәктәбе (1887 дә ачыла), 2 тегермән, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 716 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1859 да — 347, 1897 дә — 307, 1908 дә — 284, 1920 дә — 375, 1926 да — 370, 1938 дә — 209, 1949 да — 242, 1958 дә — 142, 1970 тә — 66, 1989 да — 29, 2002 дә — 30 кеше.

**ЯҢА́ СОСНО́ВКА** посёлогы, Казанның Совет р-ны составында, Биектау тимер юл станциясеннән 9 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кырлай елгасы буенда. 1997 елда 1342 кеше (ш.и. татарлар — 79%) яши. Халкының төп шөгыле — ит терлеге асрау. 1961 дә нигез салына. Оешкан көненнән Биектау р-нында, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Биектау, 1998 нең 25 ноябреннән Казанның Совет р-ны карамагында. Халык саны: 1970 тә — 979, 1989 да — 1600 кеше.

**ЯҢА́ СПАС** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 17 *км* көньяк-көнбатыштарак, Көрнәле елгасы буенда. 2010 елда 212 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Чиркәү. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Происхождение Честных древ Креста Господня чиркәве (1737 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1879 да ачыла), 7 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, кирпеч з-ды, 4 вак-төякләр кибете эшли. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Спас өязе Левашёво волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 378 ир-ат; 1920 дә — 1443, 1926 да — 1173, 1938 дә — 717, 1949 да — 452, 1958 дә — 288, 1970 тә — 230, 1979 да — 180, 1989 да — 151, 2002 дә — 230 кеше.

**ЯҢА́ СПАС** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 36 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Урман Зәе елгасы буенда. 2010 елда 335 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Алпавыт А.П.Мельгунов йорты (19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге). 18 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Бүсерәк исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, таш чыгару, балта эше һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, монда волость идарәсе урнаша; Спас чиркәве (1842 дә төзелә), земство мәктәбе (1860 елларда ачыла), шәраб-аракы з-ды, су тегермәне, 12 кибет була; һәр шимбәдә базар эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1412 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Спас волосте үзәге була, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1858 дә — 549, 1870 тә — 721, 1897 дә — 810, 1913 тә — 825, 1920 дә — 926, 1926 да — 820, 1938 дә — 774, 1949 да — 504, 1958 дә — 650, 1970 тә — 511, 1979 да — 429, 1989 да — 374, 2002 дә — 375 кеше.

**ЯҢА́ СУМАРО́КОВО** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ютазы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 349 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар 70%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Троицкий исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында монда волость идарәсе урнаша; Троицкий чиркәве, чиркәү-приход һәм земство мәктәпләре, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1520 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумароково волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 8 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 883, 1889 да — 770, 1897 дә — 984, 1910 да — 739, 1920 дә — 1041, 1926 да — 610, 1938 дә — 758, 1949 да — 667, 1958 дә — 331, 1970 тә — 362, 1979 да — 445, 1989 да — 466, 2002 дә — 422 кеше.

**ЯҢА́ СУМАРО́КОВО** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы бассейнында урнашкан. Даими яшәүчеләр юк. 18 йөздә нигез салына. 1861 елга кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 316,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Колунец волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 111, 1897 дә — 153, 1908 дә — 181, 1920 дә — 176, 1926 да — 233, 1938 дә — 234, 1949 да — 119, 1958 дә — 105, 1970 тә — 59, 1979 да — 23, 1989 да — 3 кеше, 2002 дә — 1.

**ЯҢА́ СУ́РКИНО** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 25 *км* көнчыгыштарак, Куак елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 309 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. 18 йөз ахырында Иске Бүсерәк һәм Иске Суркино авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бүсерәк, Югары Чертанлы исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, йон тетү, киез итек басу, төзелеш өчен таш чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында гыйбадәтханә, чиркәү-приход мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1294 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Ивановкасы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан — Лениногорск, 1958 дән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1795 тә — 77 ир-ат; 1889 да — 392, 1897 дә — 437, 1910 да — 498,

1920 дә — 550, 1926 да — 578, 1938 дә — 473, 1949 да — 430, 1958 дә — 574, 1970 тә — 639, 1979 да — 472, 1989 да- 311, 2002 дә — 307 кеше.

**ЯҢÁ СУЫКСЎ** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 9 *км* көньяктарак, Казан–Ульяновск автомобиль юлы буенда. 2010 елда 219 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәчет. 1665 еллардан билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр сарай) крәстияннәре катлавына керә; лашман хезмәтен үти, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл Сембер губернасының Буа өязе Иске Суыксу волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 215, 1859 да — 329, 1880 дә — 436, 1897 дә — 592, 1913 тә — 562, 1920 дә — 350, 1926 да — 708, 1938 дә — 564, 1949 да — 525, 1958 дә — 453, 1970 тә — 453, 1979 да — 363, 1989 да — 262, 2002 дә — 254 кеше.

**ЯҢÁ ТАКТАЛЫ́** авылы, Алексеев р-нында, Базарлы Матак авылыннан 22 *км* көнбатыштарак, Бизнә елгасы буенда. 2010 елда даими яшәүчеләр юк. 18 йөздә нигезләнә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Т.да тегермән һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 741,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Гусиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварынна н Алексеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 271, 1897 дә — 356. 1908 дә — 411, 1920 дә — 427, 1926 да — 256, 1938 дә — 205, 1949 да — 258, 1958 дә — 207, 1970 тә — 229, 1979 да — 157, 1989 да — 44, 2002 дә — 10 кеше (чуашлар).

**ЯҢÁ ТАТÁР ӘДӘМСУЫ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 29 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әдәм елгасы буенда. 2010 елда 71 кеше (татарлар) яши. Клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигезләнә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 20 йөз башында Я.Т.Ә.нда 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 тегермән, ярма яргыч, 2 мануфактура һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1568 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда, 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан — Алексеев, 1977 нең 29 августыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 107 ир-ат; 1859 да — 1053, 1897 дә — 1141, 1908 дә — 1952, 1920 дә — 1428, 1926 да — 890, 1938 дә — 670, 1949 да — 470, 1958 дә — 384, 1970 тә — 394, 1979 да — 266, 1989 да — 124, 2002 дә — 82 кеше.

**ЯҢÁ ТАТÁР БИСТӘСÉ**, Казанның көньяк-көнбатыш читендәге торак пункт. 1751 елда Казанның Татар бистәсендә яшәүчеләр нигезли. Я.т.б. татарларны көчләп *христианлаштыру* сәясәте көчәйгән шартларда барлыкка килә. 1749 да Казан һәм Татар бистәсе янгын казасына дучар булудан файдаланып, архиерей *Лука* (Конашевич) хакимиятләргә татарларны Казаннан куып чыгару һәм аларның җирләрен православие динендәге кешеләргә һәм чиркәү әһелләренә бирү тәкъдиме б-н мөрәҗәгать итә. Сенат бистә халкына үз урыннарында калырга рөхсәт бирә, әмма миссионерлар аларга төзелеш эшләре алып барырга комачаулык итә. Татар бистәсендә чиркәү төзелә, христиан дине әһелләре өчен йортлар корыла, зират өчен җир бүленә. Татар бистәсе халкы вәкилләре, хакимиятләргә мөрәҗәгать итеп, Казан янында җир бүлеп бирүне сорый. Сенатның 1750 ел 8 август фәрманында татарларга «...элек никадәр күләмдә җирләре булган булса... шул ук күләмдә... монастырь җирләреннән һәм якын-тирәдән» яки Поповка авылы җирләрен бирергә боерыла. 1753 тә бистәдә 128 татар йорты исәпләнә (шуларның 108 е — Татар бистәсенең төньягыннан), 1781 дә анда яшәүчеләрнең 470 е ир затыннан була. Тирә-як авыллардан килеп сабын кайнату һәм тире эшкәртү з-дларында эшләүчеләр дә шунда яши. К.Ф.Фукс мәгълүматларына караганда (19 йөзнең 1 нче яртысы), һәр елда сезонлы эш вакытында татар бистәләрендәге татарлар саны 700 кешегә арта. Я.т.б. яшәү өчен уңайсыз була. Язгы ташу вакытында ул 2,5 айга аерым утрауга әверелә, халыкка хәрәкәт итү кыенлаша. Чыганакларда теркәлгәнчә, «...ул сулардан төрле урыннарда күлләр барлыкка килә һәм алар җәй буе кипмиләр». Болар барысы да Я.т.б. халкы хуҗалыгына зыян китерә. Шуңа карамастан, бистәнең икътисади үсеше дәвам итә, моңа татар бистәләренә каршылыксыз сәүдә эшләре алып барырга рөхсәт иткән 1763 елгы фәрманнар да этәргеч була. *Яңа кануннар эшләү комиссиясе (1767–69)* эшләгән чорда Казанның татар бистәләре халкы аларның мәнфәгатьләрен кайгыртучы С.*Хәлфин* аркылы хакимияттән, рекрутлыктан, «җан башыннан» салымнан, мунча өчен түләүләрдән азат итеп, хәлләрен җиңеләйтүне; ш.у. алга таба, бигрәк тә Казанда, бернинди дә каршылыксыз сәүдә итәргә, «...кибетләрдә утырырга... тире-яры складлары, иген амбарлары тотарга, Идел буйлап түбәнгә һәм югарыга таба көймәләр йөртергә... [рөхсәт итүне], сәүдә вакытында өяз кешеләреннән комачаулыклар булдырмауны»; татарларны көчләп чукындыруны туктатуны; «...төрле дәрәҗәдәге кешеләр... шәригать һәм пәйгамбәр турында... сүгенү сүзләре кулланганга күрә», дин ирeгeн закон б-н яклауны; патшадан фәрманнар булмый торып бистәдә чиркәү төзетмәүне һ.б.ны үтенә. 1781 дә *Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы* оешканнан соң, Я.т.б. халкы үзидарә мөмкинлеге ала. 1784 нең 4 ноябрендә ратушага беренче сайлауларда Я.т.б.ннән 106 кеше катнаша. Бистә халкы тормышын җайлауда муллалар, ш.у. мөселман җәмәгатендәге абруйлы һәм мөхтәрәм кешеләр — аксакаллар, «намуслы абруй» (Бикбау Бикмәтов, Якуп Сеинов, Алил Асяков, Сәгыйть Бакыев, Гали Якупов, Давыт Измайлов һ.б.) мөһим роль уйный. Бистә халкының 2200 ир-аты 3 мәхәлләгә берләшә (20 йөз башы). Бу мәхәлләләр *Иске таш мәчет* (9 нчы Зур таш мәчет), «Тәбәнәк Бохара» мәчете (10 нчы мәчет) һәм 11 нче мәчетләргә карый. 18 йөзнең 2 нче яртысында Я.т.б.ндә 2 агач мәчет төзелә. Аның берсе, Ш.Мәрҗани мәгълүматлары буенча, «Ишкәй мулла мәчете» яки «беренче мәчет» дип йөртелгән. 19 йөз башында татар сәүдәгәрләре Габдрәхим ибне Вәлид ибне Мөсәлим ибне Мәмәш әл-Орнашбаши, Г.Г.Үтәмишев, М.И.Апанаев акчаларына 3 таш мәчет төзелә. 18 йөз ахырыннан Я.т.б. татар эшмәкәрләре пр-тиеләре туплану урынына әверелә: Казанның татар бистәләрендә булган 27 пр-тиенең 20 се Я.т.б.ндә урнаша (1799); 18 йөз ахырында — 19 йөз башында анда Апанаевларның, Аитовларның, Замановларның һ.б.ның сабын кайнату, тире эшкәртү, комач ф-калары була; 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында Үтәмишевләрнең тукыма мануф-касы һәм сабын кайнату з-ды, Г.М.Галикәевнең сабын кайнату з-ды киң таныла. Әмирханов, Сәитов, Якупов мәдрәсәләре була. Хәлфиннәр, Ф.Әмирхан, Б.Вәисов, С.Иманколый, Г.Тукай, Г.Исхакый һ.б.ның тормышы һәм эшчәнлеге Я.т.б. б-н бәйле. Окт. рев-циясеннән соң Я.т.б. милли төсмерен югалта башлый, мәчетләр ябыла, мәхәлләләр бетерелә. 1920 еллар ахырында бистәдә Казан мех комб-ты төзелә. Элекке Я.т.б. терр-ясен хәзер М.Гафури, К.Якуб, Мехчылар урамнары били.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 13. № 9791.

*Әд.:* К а л и н и н Н.Ф. Казань времён пугачёвских событий // Тр. КФАН СССР. 1959. Вып. 2; С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; Татарские слободы Казани: Очерки истории. К., 2002.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ЯҢÁ ТАУ** посёлогы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Көшкәт елгасыннан (Шушманың уң кушылдыгы) 1,5 *км* еракълыкта урнашкан. 2010 елга даими яшәүчеләр юк. 1920 елларда удмурт авылы буларак нигезләнә. Оешкан көненнән — ТАССРның Арча кантоны Арбор волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1938 дә — 77, 1949 да — 108, 1958 дә — 55, 1970 тә — 49, 1979 да — 37, 1989 да — 15 кеше, 2002 дә — даими яшәүчеләр юк.

**ЯҢÁ ТӘКЕРМӘ́Н** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 24 *км* көньяк-көнбатыштарак, Минзәлә елгасыннан 1,5 *км* еракълыкта урнашкан. 2010 елда 64 кеше (татарлар) яши. 1909 да Сарысаз Тәкермән авылыннан күчеп килүчеләр нигезли. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Тәкермән исеме б-н дә билгеле. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1913 елгы мәгълүматларга карганда, авыл җәмәгатенең имана җире 910 дис. тәшкил итә. 1916 да мәчет төзелә. 1920 гә ка-

дәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда, 1920 дән — ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1913 тә — 299, 1920 дә — 254, 1926 да — 192, 1938 дә — 182, 1949 да — 130, 1958 дә — 133, 1970 тә — 1968, 1979 да — 118, 1989 да — 64, 2002 дә — 80 кеше.

**ЯҢА́ ТӘКМӘ́К** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 15 *км* төньяктарак, Чаллы–Зәй автомобиль юлы буенда. 2010 елда 18 кеше (руслар) яши. 1913 тә нигезләнә. Оешкан көненнән — Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән — Чаллы кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 нояберennән Зәй р-нында. Халык саны: 1926 да — 133, 1938 дә — 193, 1949 да — 138, 1958 дә — 84, 1970 тә — 43, 1979 да — 43, 1989 да — 15, 2002 дә — 18 кеше.

**«ЯҢА́ ТЕА́ТР»**, к. *Театр биналары*.

**ЯҢА́ ТИМО́ШКИНО** авылы, Аксубай р-нында, Аксубай посёлогыннан 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 476 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз урталарында нигезләнә. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Бердебяково исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 859 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 37 ир-ат; 1859 да — 278, 1897 дә — 432, 1908 дә — 51, 1920 дә — 546, 1926 да — 629, 1938 дә — 670, 1949 да — 471, 1958 дә — 488, 1970 тә — 781, 1979 да — 666, 1989 да — 499, 2002 дә — 558 кеше.

**ЯҢА́ ТИНЧӘЛӘ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 33 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Тилчә елгасы буенда. 2010 елда 870 кеше (татарлар) яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, мәчет. 1686 дан билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә (лашман хезмәтен үти), кырчылык, мөгезле эре терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Т.дә 4 мәчет, 3 мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3579,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Иске Суыксу волостенда, 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 1510, 1880 дә — 1698, 1897 дә — 2094, 1913 тә — 2805, 1920 дә — 2629, 1926 да — 2539, 1938 дә — 2121, 1949 да — 1786, 1958 дә — 1727, 1970 тә — 1737, 1979 да — 1464, 1989 да — 1019, 2002 дә — 892 кеше.

**ЯҢА́ ТИНЧӘЛӘ́** посёлогы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Зөя елгасыннан 1 *км* ераклыкта. 2010 елда 11 кеше (татарлар) яши. 1930 елларның 1 нче яртысында нигезләнә. Оешкан көненнән — ТАССРның Буа кантоны Борындык волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1926 да — 158, 1938 дә — 134, 1949 да — 128, 1958 дә — 108, 1970 тә — 84, 1979 да — 37, 1989 да — 12, 2002 дә — 7 кеше.

**ЯҢА́ ТИНЧӘЛӘ́ СӨРКӘ́ (БАЙБА́К) КОЛО́НИЯСЕ**, табигать истәлеге, Буа р-ны терр-ясендә, Яңа Тинчәле һәм Шәйморза авыллары арасындагы Олы Тилчә елгасы үзәненең сулъяк яр сөзәклеге буендагы участокны били. 1987 елда билгеләнә. Мәйданы 125 *га*. Тугай һәм далаланган болын күренешләре булган 5 *км* озынлыктагы ерым-сызалар системасында сөркә-байбак (2006 да ТРның Кызыл китабыннан сызыла) колониясе яши. Бу аларның иң төньяктагы яшәү урыннарының берсе. 1995 тә — 308 оя. Дала һәм кыр карчыгасы, тимгелле йомран очрый. Үсемлекләрнең сирәк төрләре, ш.и. язгы адонис үсә.

**«ЯҢА́ ТОРМЫ́Ш»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. 1907 елның 11 ноябреннән 1909 ның февраленә кадәр Уральск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 20 саны чыга. «*Фикер*» г-тасы дәвамчысы. Нашире һәм мөхәррире — М.Мусин, чынлыкта җитәкчесе — К.*Мотыйгый*. Газетада эчке һәм тышкы сәясәт, Дәүләт Думасы эшчәнлеге турында хәбәрләр басыла. Милли-демократик басма буларак, «Я.т.» татар милли мәдәнияте һәм мәгарифе үсешен, Россия мөселманнарының рухи бердәмлеген яклап чыга, укучыларны Көнбатыш Европа илләренең иҗтимагый-сәяси тормышы б-н таныштыра. Мисырда И.Гаспринский катнашында узган мөселманнар конгрессы эшен яктырта. Татар матбугаты күзәтүләрендә газетаның системалы чыкмавына борчылу белдерелә. Даими рәвештә татар хәйрия җәмгыятьләре эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар басыла. Матур әдәбият әсәрләре, Г.Тукай һәм Г.Исхакый иҗаты турында сатирик һәм әдәби-тәнкыйть язмалары, памфлетлар, ш.и. Н.Думави, Х.Чулпаный һ.б.ның шигырьләре чыга. Сәяси характердагы мәкаләләр өчен редакция берничә тапкыр штрафка тартыла, аерым саннары конфискацияләнә. К.Мотыйгыйны кулга алгач, «Я.т.» укучыларның мөхәррирне яклап чыккан хатларын бастыра. Хөкүмәт тарафыннан ябыла.

*Әд.:* Т ө х ф ә т у л л и н Х.К. Камил Мотыйгый. К., 1992.

**ЯҢА́ ТРО́ИЦКИЙ** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 85 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 1048 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; спирт з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1740 елларга кадәр нигезләнә. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новиковка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр алпавыт крәстияннәре катлавына керә, халкы кырчылык, терлекчелек, мич чыгару, тегүчелек һ.б. б-н шөгыльләнә. 1774 тә Е.И.Пугачёв отрядлары тарафыннан талана. 20 йөз башында Троица чиркәве (1791 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1866 да ачыла), тимерче алачыгы, йон-тукыма ману йорты, су һәм пар тегермәне, шәраб з-ды, 3 вак-төякләр кибете, шимбә базары эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 350 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 206 ир-ат; 1859 да — 1073, 1897 дә — 1472, 1908 дә — 1445, 1920 дә — 1402, 1926 да — 1066, 1938 дә — 1213, 1949 да — 1137, 1958 дә — 1293, 1970 тә — 1058, 1979 да — 1047, 1989 да — 897, 2002 дә — 1137 кеше.

**ЯҢА́ ТРО́ИЦКИЙ** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чаллы елгасы (Каманың сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 1006 кеше яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1780 елларга кадәр нигезләнә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мулловка исеме б-н дә билгеле.1860 елларга кадәр удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, халкы кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве (1843–52 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1877 дә ачыла), китапханә (1903 тә ачыла), су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1475 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яр Чаллы волостенда, 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 922 дән — Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 426, 1870 тә — 818, 1897 дә — 914, 1913 тә — 839, 1920 дә — 754, 1926 да — 486, 1938 дә — 404, 1949 да — 860, 1958 дә — 491, 1970 тә — 371, 1979 да — 658, 1989 да — 608, 2002 дә — 785 кеше, 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 49%, руслар — 43 %.

**ЯҢА́ ТУМБА́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 48 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кече Чирмешән елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 291 кеше яши. Урман хуҗалыгы. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1920 елларда нигезләнә. Оешкан көненнән — ТАССРның Спас кантоны Юхмачы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 28 октябреннән — Әлки, 1987 нең 19 августыннан Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1926 да — 173,

1938 дә — 362, 1949 да — 575, 1958 дә — 1371, 1970 тә — 1860, 1979 да — 877, 1989 да — 515, 2002 дә — 399 кеше (чуашлар — 55%, руслар 33%).

**ЯҢА́ ТУРА́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 22 *км* көнчыгыштарак, Казан–Түбән Новгород автомагистрале буенда. 2010 елда 379 кеше (руслар) яши. Халыкның төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1794 тә Иске Тура авылыннан күчеп килүчеләр нигезли. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элекке экономик крәстияннәр) катлавына керә, кырчылык, терлекчелек, умартачылык, тегү, агач эшкәртү, мич чыгару, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Т.да чиркәү-приход мәктәбе (1896 да ачыла), җил тегермәне, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1526,5 дис. тәшкил итә. 1929 да «Пролетарий» (1953 тән — Ленин исем.) колхоз оеша, 1960 та «Юдино» совхозына керә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Ильинка волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 5 ир-ат; 1859 да — 178, 1897 дә — 258, 1908 дә — 302, 1920 дә — 366, 1926 да — 386, 1949 да — 239, 1958 дә — 253, 1970 тә — 273, 1979 да — 227, 1989 да — 140, 2002 дә — 348 кеше.

**ЯҢА́ УРА́Л** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 22 *км* көньяктарак, Талкыш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 4 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда Мөслим авылыннан күчеп килүчеләр нигезли. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Мөслим волостенда. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 408, 1949 да — 330, 1958 дә — 262, 1970 тә — 290, 1979 да — 172, 1989 да — 32, 2002 дә — 20 кеше.

**ЯҢА́ УСЫ́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 12 *км* көнчыгыштарак, Казанчы елгасы буенда. 2002 елда 434 кеше (татарлар) яши. Халыкның төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1750 дә нагайбәк казакълары авылы буларак нигезләнә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Усы исеме б-н дә билгеле; 1930–63 тә рәсми документларда 2 авыл буларак теркәлгән: Зар-Усы һәм Керәш-Усы. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлекчелек, умартачылык, тегү, агач эшкәртү, мич чыгару, тимерчелек б-н шөгыльләнә. Милли составы буенча татарларга (керәшен), русларга һәм марийларга бүленә. Халыкның төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү, чана ясау, йөк ташу. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, 4 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2828 дис. тәшкил итә. 1922 гә кадәр — Уфа губернасының Бәләбәй өязе Нагайбәк волостенда, 1922 дән — Башкорт АССРның Бәләбәй кантонында, 1926 ның 25 гыйнварыннан — ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Мөслим р-нында. Халык саны: 1824 тә — 96 ир-ат; 1870 тә — 966, 1902 дә — 786 ир заты; 1917 дә — 1963, 1938 дә — 638, 1949 да — 1094, 1958 дә — 746, 1970 тә — 613, 1979 да — 570, 1989 да — 452, 2002 дә — 449 кеше.

**ЯҢА́ ҮБИ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 21 *км* көнчыгыштарак, Кече Чынлы елгасы (Зөя бассейны) буенда. 2010 елда 695 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөз ахырында нигезләнә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Куликеево исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлекчелек, тимерчелек, агач эшкәртү, такта яру, йон тетү б-н шөгыльләнә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 980,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда, 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1747 дә — 182 ир-ат; 1859 да — 412, 1897 дә — 664, 1913 тә — 900, 1920 дә — 912, 1926 да — 1056, 1938 дә — 1156, 1949 да — 1190, 1958 дә — 1131, 1970 тә — 1311, 1979 да — 1102, 1989 да — 734, 2002 дә — 713 кеше.

**ЯҢА́ ҮЗИ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 19 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 397 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Язучы Г.Кашапов музее. 2 мәчет, ш.и. элекке 2 нче Җамигъ мәчет (1911 дә төзелгән; архит-ра истәлеге). 18 йөзнең 2 нче яртысында нигезләнә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ү.дә 2 мәчет, мәктәп, тимерче алачыгы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2371,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостенда, 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1859 да — 731, 1897 дә — 1501, 1908 дә — 1528, 1920 дә — 1953, 1926 да — 989, 1938 дә — 1269, 1949 да — 841, 1958 дә — 747, 1970 тә — 850, 1979 да — 720, 1989 да — 474, 2002 дә — 450 кеше.

**ЯҢА́ ҮРГӘГА́Р** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 9 *км* көнчыгыштарак, Актай елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 178 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигезләнә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ү.да мәчет, 2 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1367 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Мораса волостенда, 1920 дән — ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Әлки р-нында. Халык саны: 1859 да — 795, 1897 дә — 1041, 1908 дә — 938, 1920 дә — 1129, 1926 да — 899, 1938 дә — 698, 1949 да — 447, 1958 дә — 435, 1970 тә — 445, 1979 да — 345, 1989 да — 240, 2002 дә — 219 кеше. Я.Ү.да Сов. Союзы Герое З.Г.Исхаков туган.

**ЯҢА́ ҮТӘМЕ́Ш** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 47 *км* көньяк-көнбатыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 6 кеше (татарлар) яши. 1770 елларда Иске Үтәмеш авылыннан күчеп килүчеләр нигезли. 1860 ка кадәр типтәр катлавына керә, халкы кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 564 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спиридоновка волостенда, 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 12 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1785 тә — 39 ир-ат; 1889 да — 129, 1910 да — 207, 1920 дә — 327, 1926 да — 258, 1938 дә — 249, 1949 да — 245, 1958 дә — 205, 1970 тә — 183 , 1979 да — 132, 1989 да — 39, 2002 дә — 18 кеше.

**«ЯҢА́ ФИКЕ́Р»**, иҗтимагый-сәяси газета. Эчке Россия мөселман эшләре комис-тының Уральск бүлеге органы. 1920 елда Уральск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә; беренче саны 1920 нең 6 февралендә чыга. Мөхәррире — К.*Мотыйгый*.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; И б р а г и м о в Г. Сочинения. К., 1978. Т. 5.

**ЯҢА́ ЧАЛЛЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матактан 9 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чаллы елгасы (Актайның уң кушылдыгы) бассейнында урнашкан. 2010 елда 234 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз урталарына кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ч. да 3 мәчет, 3 мәктәп, 7 җил тегермәне, 3 ярма ярдыргыч, 3 тимерче алачыгы, йон тетү, 1 мануфактура, 9 бакалея кибете эшли. Авыл җәмгатенең имана җире 3909,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостенда, 1920 дән — ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 231 ир-ат; 1859 да — 1739, 1908 дә — 2783, 1920 дә — 2727, 1926 да — 1790, 1938 дә — 1321, 1949 да — 951, 1958 дә — 822, 1970 тә — 809, 1979 да — 610, 1989 да — 412, 2002 дә — 308 кеше.

**ЯҢА́ ЧӘБИЯ́** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 31 *км* көньяктарак, Баш-Арбаш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 65 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 18 йөз урталарына кадәр нигезләнә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Чәбия исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 су тегермәне, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 712,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 26 ир-ат; 1859 да — 323, 1897 дә — 426, 1908 дә — 488, 1920 дә — 460, 1926 да — 454, 1949 да — 304, 1958 дә — 246, 1970 тә — 274, 1979 да — 220, 1989 да 121, 2002 дә — 86 кеше.

**ЯҢА́ ЧӘКЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 24 *км* көньяктарак, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 125 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 57%, чуашлар — 42%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1723 кә кадәр нигезләнә. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ч.дә мәчет, мәдрәсә, 5 сәүдә-сәнәгать пункты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 738,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Городище волостенда, 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 416, 1897 дә — 753, 1913 тә — 1016, 1920 дә — 932, 1926 да — 613, 1938 дә — 837, 1949 да — 707, 1958 дә — 625, 1970 тә — 533, 1979 да — 420, 1989 да — 188, 2002 дә — 144 кеше.

**ЯҢА́ ЧӘКЕ́ УРМА́Н ДАЛАСЫ́**, к. *Кирәмәт.*

**ЯҢА́ ЧӘЧКА́П** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Лашчы елгасы буенда. 2010 елда 530 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигезләнә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ч.та мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1524,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Килдураз волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән — Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 482, 1897 дә — 857, 1908 дә — 986, 1920 дә — 1078, 1926 да — 763, 1938 дә — 1010, 1949 да — 844, 1958 дә — 840, 1970 тә — 1082, 1979 да — 771, 1989 да — 575, 2002 дә — 548 кеше.



Яңа Чишмә авылы. Гомуми күренеше.

**ЯҢА́ ЧИРКӘ́С** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Нократ елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 1 кеше яши. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигезләнә. 1860 елга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ч.тә тимерче алачыгы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Иске Чиркәс авылын да кертеп) 386,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 283 (Иске Чиркәс авылын да кертеп), 1897 дә — 444, 1908 дә — 542 (Иске Чиркәс авылын да кертеп), 1920 дә — 309, 1926 да — 305, 1949 да — 175, 1958 дә — 169, 1970 тә — 104, 1979 да — 35, 1989 да 15 (руслар, марилар), 2002 дә — 1 кеше.

**ЯҢА́ ЧИШМӘ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 59 *км* көнбатыштарак, Баграж елгасы (Чишмәнең уң кушылдыгы) бассейнында урнашкан. 2010 елда 23 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1927 дә Иске Баграж-Елховой авылыннан күчеп килүчеләр нигезли. Оешкан көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Кузай волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1932 нең февраленнән — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 гыйнварыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1938 дә — 224, 1949 да — 257, 1958 дә — 241, 1970 тә — 201, 1979 да — 147, 1989 да — 58, 2002 дә — 38 кеше.

**ЯҢА́ ЧИШМӘ́** авылы, Яңа Чишмә р-ны үзәге. ТРның үзәгендә, Шонталы тимер юл станциясеннән (Ульяновск–Уфа линиясе) 75 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. Казаннан 197 *км.* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 14179 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча руслар — 64%, татарлар — 29%) яши. Азык сәнәгате пр-тиеләре (майсызландырылган коры сөт з-ды, «Татарстан сөте» АҖ, икмәк комб-ты), кирпеч з-ды. Гимназия, башлангыч мәктәп, һөнәр уч-щесе. Балалар иҗаты үзәге, спорт-техника клубы, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе; музыка мәктәбе. Район мәдәният йорты, 2 китапханә. Район үзәк хастаханәсе. Покров Мәрьям Ана гыйбадәтханәсе, мәчет. 1652 дә Кама аръягы чик сызыгында (к. *Кама аръягы иске чик сызыгы*) кальга буларак нигезләнә. Башлап Чишмә ныгытмасыннан (Иске Чишмә авылы) гаиләләре б-н 100 укчы күчерелә, ш.у. Яр Чаллы авылыннан (хәзер Чаллы шәһәре составында) 50 дәүләт крәстияне килеп утыра. 1655 тә Смоленскидан 127 шляхта вәкиле килеп урнаша, 1674 тә аларга җир биләмәләре бирелә. 17 йөзнең 2 нче яртысындагы рәсми чыганакларда Я.Ч. — шәһәрчек, 1708 дән Казан губернасының шәһәр яны бистәсе буларак теркәлә. 17 йөзнең 2 нче яртысында — 18 йөзнең 1 нче яртысында еш кына нугайлар, башкортлар, кыргыз-кайсаклар һөҗүменә дучар була. 1654 тә нугайлар Я.Ч. тирәсендәге саклану корылмаларын җимерәләр, 1717 дә кальга алына һәм Кече Кыргыз Урдасы ханы Әбелхәер отрядлары тарафыннан яндырыла. 1730 елларда төзелә торган Кама аръягы һәм Оренбург ныгытылган чик сызыкларына күчерелгән йомышлы кешеләр урынына, Я.Ч. гә отставкадагы солдатлар, унтер-офицерлар китереп урнаштырыла (1795 елгы 5 нче ревизия материалларына караганда, 698 ир-ат яши). 1830 елларда отставкадагы (игенче) солдатлар дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә һәм 1860 елларга кадәр шул катлауда кала; кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, тире эшкәртү, чана ясау, таш әзерләү б-н шөгыльләнә. 1846 да



Яңа Чишмә авылы. Район хакимияте бинасы.

Я.Ч.дә — Дәүләт милке министрлыгы мәктәбе (1867 дә земство мәктәбе, 1910 да 2 сыйныфлы алтыеллык мәктәп итеп үзгәртелә), 1896 да — икенче земство мәктәбе, 1916 да югары башлангыч уч-ще ачыла. 20 йөз башында волость идарәсе, Троица (1794; архит-ра истәлеге) һәм Петропавел (1915) чиркәүләре, 3 тимерче алачыгы, 4 май язу һәм 2 йон тетү йорты, 8 ярма яргыч, 2 су тегермәне, 10 вак-төякләр һәм 1 казна шәраб кибете, 3 сыраханә була; җомга базары һәм 1–8 октябрьдә ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 9440 дис. тәшкил итә. Гражданнар сугышы елларында Я.Ч. «Сәнәкчеләр» фетнәсен бастыру вакытында (1920) зыян күрә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Чишмә волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән Чистай р-ны составында, 1983 нең 26 апреленнән — район үзәге итеп билгеләнә. Халык саны: 1859 да — 2678, 1906 да — 5646, 1910 да — 5107, 1938 дә — 4000, 1949 да — 3500, 1958 дә — 3116, 1970 тә — 2749, 1979 да — 1969, 1989 да — 3450, 2002 дә — 4576 кеше.

**ЯҢА́ ЧИШМӘ́ РАЙОНЫ́**, ТРның үзәк өлешендә урнашкан. Мәйданы — 1317,5 *км*$^2$. 15 авыл җирлеген, 30 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Яңа Чишмә авылы. Халкы — 13386 кеше (2017), 2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 49,5%, татарлар — 44,2%. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*$^2$ га 12 кеше. 1930 елның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр район терр-ясе Казан губернасының Чистай өязендә, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. Оешкан көненнән Я.Ч.р.на 33 авыл советы, 63 торак пункт керә, аларда 47354 (руслар — 40370, татарлар — 6476) кеше яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1498 *км*$^2$, халкы — 42,9 мең кеше, 25 авыл советы, 79 торак пункты була. 1944 нең 19 февралендә Я.Ч.р.ның бер өлеше яңа оештырылган *Ямаш районына* кушыла (1956 ның 7 декабрендә кире кайтарыла), нәтиҗәдә, районның мәйданы 858 *км*$^2$ га кала. 1960 та район 1629,1 *км*$^2$ җир били, аңа 12 авыл советы, 76 торак пункт керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Я.Ч.р. бетерелә, терр-ясе Әлмәт һәм Чистай р-ннарына кушыла. 1983 нең 26 апрелендә район кире кайтарыла. 1984 нең 3 июлендә Ялантау, Кармалы, Сосновка авыл советлары Түбән Кама р-нына бирелгәч, районның хәзерге чикләре билгеләнә.




Я.Ч.р.ның рельефы — калкулыклы тигезлек (биеклеге 120–170 *м*). Чишмә һәм аның кушылдыгы Кичү елгасы ага. Җирләре селтесез, көлсу һәм карбонатлы кара, карасу соры һәм соры урман туфраклы. Терр-ясенең 10% ы — урманлык. Нефть ятмалары, комсыл балчык, комташ, мергель ятмалары бар. Саклаулы табигать объектлары: *Чишмә* елгасы, *Үргәнеч ботаника тыюлыгы, Коржинский сөзәклекләре*. Район терр-ясендә Болгар һәм Алтын Урда чорына караган 130 дан артык археол. истәлекләр табыла. Я.Ч.р.нда а.х. тармагы алга киткән. Терлекчелек нык үскән. А.х. җирләре — 106,2 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр — 88,6 мең *га* (2018). Сабан бодае, арыш, арпа, солы, тары, борчак игелә, чөгендер үстерелә. Я.Ч.р.нда 11 а.х. товарлары житештерү пр-тиесе эшли (2016). Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгенә урнашкан. Район терр-ясеннән Казан–Оренбург, Чирмешән–Яңа Чишмә автомобиль юллары уза. Районда 18 гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. 10 тулы булмаган урта, 4 урта, 4 мәктәп-балалар бакчасы; балалар сәнгать мәктәбе, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, 1 гимназия; 1 а.х. лицее; 20 мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесе, 25 клуб, 23 китапханә, 1 хастаханә, 23 фельдшер-акушерлык пункты бар. Төбәк тарихы (Яңа Чишмә а.), Халык иҗаты һәм көнкүреше (Зирекле а.) музейлары эшли.Татар һәм рус телләрендә «Яңа Чишмә хәбәрләре» – «Шешминская новь» район г-талары нәшер ителә.

*Әд.:* На Засечной черте: Из прошлого и настоящего Новошешминского района Татарстана. К., 2007.

**ЯҢА́ ЧОКАЛЫ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 9 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чынлы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 387 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, чөгендер игү. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигезләнә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, (лашман хезмәтен үти), җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ч.да 3 мәчет, 2 мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1835,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Городище волостенда, 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 720, 1897 дә — 1584, 1913 тә — 2193, 1920 дә — 2172, 1926 да — 2406, 1938 дә — 2184, 1949 да — 1842, 1958 дә — 1366, 1970 тә — 1102, 1979 да — 812, 1989 да — 487, 2002 дә — 424 кеше.

**ЯҢА́ ЧУА́Ш ӘДӘМСУЫ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әдәм елгасы буенда. 2010 елда 327 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигезләнә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ч.Ә.нда земство мәктәбе (1900 дә ачыла), 2 тегермән, ярма яргыч, 1 казна шәраб, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1207 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәмсуы волостенда, 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 апреленнән — Алексеев, 1977 нең 29 августыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1859 да — 390, 1897 дә — 693, 1908 дә — 706, 1920 дә — 732, 1926 да — 418, 1938 дә — 441, 1949 да — 404, 1958 дә — 440, 1970 тә — 580, 1979 да — 496, 1989 да — 331, 2002 дә — 356 кеше.

**«ЯҢА́ ЧУКЫНДЫРЫЛГАННА́Р КОМИ́ССИЯСЕ»**, к. *Яңа чукындырылганнар конторасы.*

**ЯҢА́ ЧУКЫНДЫРЫЛГАННА́Р КОНТО́РАСЫ**, Казан һәм Түбән Новгород губерналарындагы рус булмаган халыкларны христианлаштыру сәясәте үткәрү өчен Изге Синодның 1731 ел 23 август фәрманы нигезендә оештырыла. 1731–34 тә — Яңа чукындырылганнар комиссиясе. Әҗнәбиләрне христианлаштыруның иң зур акциясе «Архимандритны берничә рухани белән яңа чукындырылганнарны христиан законнарына өйрәтү өчен төрле губерналарга җибәрү һәм яңа чукындырылганнарга бүләк ителгән өстенлекләр турында» *Император Анна Иоанновна Фәрманын* (1740 ел 11 сент.) үтәү барышында гамәлгә ашырыла. Я.ч.к. җитәкчесе Дмитрий Сеченов *Лука* (Конашевич) б-н бергә Идел буенда яшәүче рус булмаган халыкларны хәрби командалар ярдәмендә христианлаштыру буенча киң кампания башлый. Бары 1742–44 тә генә Казандагы һәм Казан өязендәге 536 мәчетнең 418 е җимертелә. Рус булмаган халыкларны христианлаштыру өчен зур суммада акча бүленә, аның беркадәр өлеше православие храмнары төзетү, мәктәпләр ачу, яңа чукынганнарга түләү өчен бирелә. Яңа чукындырылганнарның һәркайсы бакыр тәре, күлмәк-ыштан, тула чикмән, баш киеме, бияләй, аяк киеме (оек һәм башмак) ала. Танылган затларга көмеш тәре, кафтан, итекләр бирелә. Моннан тыш ир-атларга 50 тиеннән 1,5 сумга кадәр акча бирелергә тиеш була. 1741–64 тә Я.ч.к.н финанслау өчен якынча 360 мең сум карала (гамәлдә исә якынча 160 мең сум бүленә). Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә Россия империясендә башка диндәге 400 меңнән артык әҗнәби, ш.и. 12 меңнән артык татар чукындырыла. Екатерина II идарә иткәндә православиеле булмаган халыкларга карата алып барылган сәясәтнең либеральләшүе Я.ч.к.н гамәлдән чыгаруга китерә (Сенатның 1764 ел 6 апр. фәр-

маны). Я.ч.к.ның җитәкчеләре — Алексий Раифский (1731–38), Дмитрий Сеченов (1738–42), Сильвестр Головацкий (1742–50), Евмений Скаловский (1750–64). Ш.у.к. *Православие миссионерлыгы*, *Христианлаштыру*.

*Әд.:* Ислаев Ф.Г. Ислам и православие в Поволжье XVIII столетия: От конфронтации к терпимости. К., 2001; Ногманов А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в российском законодательстве второй половины XVI – XVIII вв. К., 2002. *А.В. Климин.*

**ЯҢА́ ЧҮПРӘЛЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 1 *км* төньяктарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2010 елда 1041 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәдәният йорты. 18 йөздә нигезләнә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Новый Дрожжаной Куст исеме б-н дә билгеле. 1860 ка кадәр дәүләт крәстияннәре катлавына (лашман хезмәтен үти) керә, халкы кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1895 елгы мәгълүматларга караганда, Я.Ч.дә мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1198,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Чүпрәле волостенда, 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 феврале ннән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 858, 1897 дә — 1052, 1913 тә — 1320, 1920 дә — 1086, 1926 да — 982, 1938 дә — 1330, 1949 да — 781, 1958 дә — 767, 1970 тә — 853, 1979 да — 828, 1989 да — 904, 2002 дә — 1051 кеше.

**ЯҢА́ ЧҮРИЛЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 30 *км*, Кече Мишә бассейнында урнашкан. 2010 елда 580 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 50%, руслар — 44%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. Психоневрология интернаты. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигезләнә. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, кырчылык, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ч.дә Троица чиркәве, земство мәктәбе (1867 дә ачыла), вак кредит ширкәте, земство хастаханәсе, даруханә, вет. фельдшерлык пункты, 4 тимерче алачыгы, 2 мануфактура-бакалея, 1 казна шәраб, 3 вак-төякләр кибете, 2 йон-тукыма ману йорты була; сишәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1534,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дә — Арча кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Саба р-нында, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле р-ны үзәге, 1956 ның 14 маеннан — Саба, 1956 ның 23 июленнән Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 389, 1897 дә — 779, 1908 дә — 687, 1920 дә — 915, 1926 да — 894, 1938 дә — 533, 1958 дә — 545, 1970 тә — 284, 1979 да — 198, 1989 да — 581, 2002 дә — 602 кеше.

**ЯҢА́ ЧУТЕ́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 55 *км* көньяктарак, Югары Кандыз елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 416 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында нигезләнә. 1860 ка кадәр халкы асабалар катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ч.дә мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2571 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Салих волостенда, 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1822 дә — 26 ир-ат; 1859 да — 392, 1889 да — 694, 1910 да — 1143, 1920 дә — 1256, 1926 да — 898, 1938 дә — 924, 1949 да — 700, 1958 дә — 643, 1970 тә — 792, 1979 да — 687, 1989 да — 542, 2002 дә — 474 кеше.

**ЯҢА́ ЧЫКАЛДА́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 74 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Удмурт Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 11 кеше (руслар, марилар) яши. 1858 дә нигезләнә. Халкының төп шөгыле — җир эшкәртү, терлекчелек, агач савыт-саба ясау. 20 йөз башында Я.Ч.да земство мәктәбе (1896 да ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 822,8 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Пьянобор волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1927 дән Чаллы кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1887 дә — 655, 1905 тә — 1023, 1920 дә — 815, 1926 да — 925, 1938 дә — 748, 1949 да — 551, 1958 дә — 356, 1970 тә — 204, 1989 да — 40, 2002 дә — 16 кеше.

**ЯҢА́ ЧЫНЛЫ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Тилчә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 72 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 елларда нигезләнә. Оешкан көненнән ТАССРның Буа кантоны Иске Шәйморза волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән Буа р-нында. Халык саны: 1926 да — 624, 1938 дә — 722, 1949 да — 318, 1958 дә — 449, 1970 тә — 540, 1979 да — 555, 1989 да — 167, 2002 дә — 111 кеше.

**ЯҢА́ ЧЫРШЫЛЫ́** посёлогы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 14 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәчкәрә елгасы буенда. 2010 елда 457 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 78%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1770 елларда нигезләнә. Баштагы атамасы — Каратай, 19–20 йөзләр чыганакларында полковник Маслов хуторы дип тә исемләнә, 1908 еллардан хәзерге атамасын йөртә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Каратай волостенда, 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1785 тә — 21 ир-ат; 1910 да — 18, 1920 дә — 153, 1926 да — 197, 1938 дә — 186, 1949 да — 215, 1958 дә — 290, 1970 тә — 285, 1979 да — 458, 1989 да — 409, 2002 дә — 530 кеше.

**ЯҢА́ ШАШЫ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 25 *км* төньяктарак, Шашы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 196 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ш.да мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Кече Шашы авылын да кертеп) 1199 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) волостенда, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 101 ира-та; 1859 да — 634, 1897 дә — 699, 1908 дә — 743, 1920 дә — 631, 1926 да — 675, 1938 дә — 472, 1949 да — 349, 1958 дә — 309, 1970 тә — 289, 1979 да — 255, 1989 да — 221, 2002 дә — 203 кеше.

**ЯҢА́ ШИГАЛИ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан–Теләче автомобиль юлында. 2012 елда 305 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 51%, руслар — 43%) яши. Кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигезләнә. 1861 гә кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.Ш.дә чиркәү-приход мәктәбе (1890 да ачыла), 2 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1058,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Казан өязе Кощаково волостенда, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 399, 1897 дә — 517, 1908 дә — 584, 1920 дә — 624, 1926 да — 600, 1949 да — 286, 1958 дә — 206, 1970 тә — 218, 1979 да — 162, 1989 да — 226, 2002 дә — 225 кеше.

**ЯҢА́ ШИГАЛИ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 16 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2012 елда 239 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөзнең 1 нче чирегенә кадәр нигезләнә. 1860 ка кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 713 дис. тәш-

кил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Уби волостенда, 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән — Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1747 дә — 187 ир-ат; 1859 да — 308, 1897 дә — 541, 1913 тә — 648, 1920 дә — 830, 1926 да — 1131, 1938 дә — 652, 1949 да — 776, 1958 дә — 766, 1970 тә — 642, 1979 да — 549, 1989 да — 314, 2002 дә — 297 кеше.

*Әд.:* Гафаров И.Ә. Туган як мирасы. К., 2017.

**ЯҢА́ ШИМБЕ́Р** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 16 *км* көнбатыштарак, Ашыт елгасыннан 1 *км* ераклыкта. 2010 елда 60 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1724 тән билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Борисовские Отары исеме б-н дә билгеле. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 720,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Күлле Киме волостенда, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 69 ир-ат; 1859 да — 711, 1897 дә — 573, 1908 дә — 628, 1920 дә — 495, 1926 да — 442, 1938 дә — 420, 1949 да — 315, 1958 дә — 214, 1970 тә — 222, 1979 да — 190, 1989 да — 94, 2002 дә — 75 кеше.

**ЯҢА́ ШӨГЕ́Р** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 33 *км* көньяк-көнбатыштарак, Урман Чишмәсе елгасы буенда. 2010 елда 263 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәчет. 1919 да нигезләнә. Оешкан көненнән — ТАССРның Бөгелмә кантоны Шөгер волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 447, 1938 дә — 441, 1949 да — 371, 1958 дә — 336, 1970 тә — 346, 1979 да — 300, 1989 да — 217, 2002 дә — 269 кеше. 1943 тә Я.Ш. янындагы 1 нче скважинада Татарстанның беренче тонна нефте табыла.

**ЯҢА́ ЫРГА́** авылы, Балык бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе авылыннан 29 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ырга елгасы буенда. 2010 елда 176 кеше (татарлар) яши. Кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1710 нан билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Тулуши исеме б-н дә билгеле. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 607 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостенда, 1920 дән — ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Салтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 29 ир-ат; 1859 да — 282, 1897 дә — 470, 1908 дә — 542, 1920 дә — 578, 1926 да — 526, 1949 да — 504, 1958 дә — 494, 1970 тә — 498, 1989 да — 296, 2002 дә — 227 кеше.

**ЯҢА́ ЭСЛӘ́К** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 84 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бимә елгасы буенда. 2010 елда 32 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Клуб. 1928 дә Иске Эсләк авылыннан күчеп килүчеләр нигезли. Оешкан көненнән — Красный Бор р-нында, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1938 дә — 339, 1949 да — 319, 1958 дә — 283, 1970 тә — 220, 1989 да — 65, 2002 дә — 45 кеше.

**ЯҢА́ ЮЛ** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 27 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычыннан 5 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 111 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 елларда нигезләнә. Оешкан көненнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1938 дә — 266, 1949 да — 278, 1958 дә — 221, 1970 тә — 272, 1979 да — 159, 1989 да — 102, 2002 дә — 118 кеше.

**ЯҢА́ ЮЛ РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1935 елның 10 февралендә Ворошилов р-ны буларак оештырыла. Үзәге — Теләнче Тамак авылы. 1920 гә кадәр Уфа губернасының — Минзәлә, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Минзәлә һәм Чаллы кантоннарында, 1930 дан Минзәлә, Сарман һәм Чаллы р-ннарында. 1940 та мәйданы — 862 *км*², халкы — 26,9 мең кеше, 20 авыл советы, 58 торак пункт була. 1956 да район 869,6 *км*² җир били, 17 авыл советын, 61 торак пунктны берләштерә. 1957 нең 29 ноябрендә Ворошилов р-ны Я.Ю.р. итеп үзгәртелә. 1959 ның 12 октябрендә район бетерелә, терр-ясе Минзәлә һәм Сарман р-ннарына бирелә.

**ЯҢАБИРДЕ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 11 *км* төньяктарак, Туйма елгасы буенда. 2010 елда 330 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 1710 га кадәр Иске Юмья авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Теремшур исеме б-н дә билгеле.18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек, йөк ташу б-н шөгыльләнә. 1840 елларда Я.дә Тихие Горы авылыннан күчеп килгән руслар урнаша. 1879 елгы мәгълүматларга караганда, Я.дә ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1158,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1920–21 дә — Вятка автономияле өлкәсендә, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән — Чаллы кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1781 дә — 69 ир-ат; 1859 да — 222, 1887 дә — 314, 1920 дә — 411, 1926 да — 441, 1938 дә — 422, 1949 да — 308, 1958 дә — 374, 1970 тә — 409, 1979 да — 326, 1989 да — 317, 2002 дә — 346 кеше.

**ЯҢАВЫ́Л** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 21 *км* көнбатыштарак, Әнҗерә елгасы буенда. 2010 елда 34 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1920 елларда нигезләнә. Оешкан көненнән ТАССРның Алабуга кантоны Алабуга волостенда, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 нобреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1926 да — 16, 1938 дә — 236, 1949 да — 218, 1958 дә — 196, 1970 тә — 135, 1979 да — 98, 1989 да — 61, 2002 дә — 33 кеше.

**ЯҢАВЫ́Л** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бәркләт елгасы буенда. 2010 елда 325 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1929 да нигезләнә. Оешкан көненнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1938 дә — 517, 1958 дә — 362, 1970 тә — 422, 1979 да — 396, 1989 да — 340, 2002 дә — 331 кеше.

**ЯҢАВЫ́Л** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 38 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 94 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәчет. 1870 елларда Мордва Чаллысы авылыннан күчеп килүчеләр нигезли. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Мордово Новое, Новинское, Янасальский Выселок исемнәре б-н дә билгеле, 1920 еллардан — Татар Мордвасы, 2002 дән хәзерге исемен йөртә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда. 1920 дән — ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1920 дә — 167, 1926 да — 128, 1938 дә — 139, 1949 да — 148, 1958 дә — 114, 1970 тә — 136, 1989 да — 88, 2002 дә — 86 кеше.

**ЯҢАВЫ́Л** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 46 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш. 2010 елда 142 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Тулы булма-

ган урта мәктәп, клуб. Китапханә. Мәчет. 18 йөздә Айбаш авылыннан күчеп килүчеләр нигезли. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кулька-Куюк, Айбаш Киюги, Новая Опса, Яна-Иль исемнәре б-н дә билгеле. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек, кортчылык, агач эшләре, тимерчелек, аяк һәм өс киемнәре тегү, урман кисү, йон тетү, йөк ташу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, җил тегермәне, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 633,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 65 ир-ат; 1859 да — 446, 1897 дә — 722, 1908 дә — 832, 1920 дә — 696, 1926 да — 946, 1938 дә — 769, 1949 да — 665, 1958 дә — 546, 1970 тә — 466, 1979 да — 328, 1989 да — 188, 2002 дә — 163 кеше.

**ЯҢАВЫ́Л** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Зөя елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 38 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Клуб. 1920 елларда нигезләнә. Оешкан көненнән ТАССРның Буа кантоны Буа волостенда. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1926 да — 110, 1938 дә — 249, 1949 да — 215, 1958 дә — 202, 1970 тә — 304, 1979 да — 196, 1989 да — 87, 2002 дә — 50 кеше.

**ЯҢАВЫ́Л** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Батрас елгасы буенда. 2010 елда 3 кеше яши. 1928 дә нигезләнә. Оешкан көненнән — ТАССРның Чаллы кантоны Кузай волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән — Зәй р-нында. Халык саны: 1938 дә — 169, 1958 дә — 80, 1970 тә — 79, 1979 да — 46, 1989 да — 15, 2002 дә — 8 кеше.

**ЯҢАВЫ́Л** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 1 кеше яши. 19 йөз башында Омар авылыннан күчеп килүчеләр нигезли. Беренче атамасы — Липовка.1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 286 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Троица-Сәкинәс волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 55, 1897 дә — 117, 1908 дә — 200, 1920 дә — 109, 1926 да — 93, 1938 дә — 76, 1949 да — 88, 1958 дә — 60, 1970 тә — 37, 1979 да — 29, 1989 да — 3, 2000 дә — 8 кеше (руслар).

**ЯҢАВЫ́Л РАЙОНЫ́**, БР ның төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 2094 *км*². Үзәге — Яңавыл шәһәре (Уфадан 183 *км* ераклыкта). Халкы — 44911 кеше, ш.и. Яңавылда — 25747 кеше (2017). Татарлар саны: 1970 тә — 14052, 1979 да — 10323, 1989 да — 14199, 2002 дә — 10803, 2010 да — 10950 кеше. Район составына 14 татар, 15 башкорт-татар, 1 рус-татар, 1 башкорт-татар-удмурт торак пункты керә. Иң зур татар авыллары: Истәк (2016 да — 350 кеше), Байгуҗа (483), Иске Кодаш (305), Ишбулды (252), Әхтиял (181). Татарларның күпчелеге район үзәгендә (2010 да — 8034 кеше) тупланган. Борынгы авыллар: Байгуҗа (1653 ел), Әхтиял (17 йөз уртасы), Гөтбер (1683), Уракай (1689). 20 йөз башында Әхтиял, Байгуҗа (2, алар каршында мәктәпләр) һәм Гөтбер авылларында мәчетләр эшли. Хәзерге вакытта (2015/16 уку елында) районның 4 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 13 ендә татар теле фән буларак укытыла. Татар милли үзәге, «Дебют» балалар студиясе дә булган «Хәят» татар халык театры (1930 дан), «Чулпан» татар халык фольклор ансамбле (1990 нан) эшли. Үзәк район китапханәсендә «Татар көнкүреше» күргәзмәсе бар. Татар һәм рус телләрендә «Яңавыл таңнары» – «Янаульские зори» район г-талары нәшер ителә. График Э.Я.*Зариповның* (2011) һәм районда туган билгеле татар шәхесләре юбилейларына багышлап (Сов. Союзы Герое Г.Х.*Хәйдәршинның* тууына — 100, РСФСР һәм Башкортстан АССРның халык артисты Р.А.*Гәрәевнең* тууына — 55, әдәбият галиме Н.Г.*Юзиевнең* тууына — 80, язучы Ә.М.*Маликовның* тууына — 90, шагыйрь, прозаик һәм публицист Г.Г.*Әмиринең* тууына — 100, шагыйрә С.Г.*Сөләймановаңың* тууына — 85 ел) күргәзмәләр үткәрелә. Я.р.нда язучы Н.С.*Фәттах*, шагыйрь И.Г.*Юзеев*, драматург Р.Ф.*Ишморат*, әдәбият галиме Н.Г.*Юзиев* туган.

**ЯҢАЛИ́Ф** (Janalif), Россиянең төрки телле халыклары зыялылары арасында барган кискен бәхәсләрдән соң 1927 елның 3 июлендә ТАССР ХКС тарафыннан кабул ителгән, латин язуына нигезләнгән алфавит.

Татар мәдәниятенең күп кенә эшлеклеләре (Г.Ибраһимов, Г.Шәрәф һ.б.) татар халкы өчен традицион булган гарәп язуын алмаштыруга каршы чыгалар; ләкин И.В.Сталин басымы астында алфавитны алмаштыру законлаштырыла. Әлеге гамәл татар мәдәнияте үсешендә авыр нәтиҗәләргә — дәвамчылыкта буыннар бәйләнеше өзелүгә, татар халкының зур өлешенең белемлелек дәрәҗәсенә гаять тискәре йогынты ясый.

Алфавитта 9 хәреф (Aa, Əə, Ee, Ii, Oo, Өө, Uu, Yy, Ьь) сузык авазларны белдерү өчен, 24 хәреф (Вв, Cc, Cc, Dd, Ff, Gg, Ƣƣ, Hh, Jj, Kk, Ll, Mm, Nn, Ꞑꞑ, Pp, Qq, Rr, Ss, Şş, Tt, Vv, Xx, Zz, Ƶƶ) тартык авазларны белдерү өчен хезмәт итә. Һәмзәне билгеләү өчен апостроф (') кулланыла. Һәмзә — бугаз авазы, саңгырау тартык. Бу авазны әйткәндә, тавыш ярылары бер-берсенә якын килеп йомылалар һәм һава басымы б-н ачылалар, шул вакыт шартлау барлыкка килә, мәс., ma'may (маэмай), tə'sir (тәэсир). «*Яңалиф*» журналында басыла (4 нче сан, 1927 ел). Я.кә изоморфизм (хәрефләрнең һәм авазларның бер үк мәгънә бирүләре) принцибы хас. 1939 да Я. рус алфавитына нигезләнгән графика б-н алыштырыла. Ш.у.к. *Латин язуы.*

*Әд.:* Курбатов Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. К., 1999; Гарипова З.Г. Заглядывая в прошлое // Языковая политика в Республике Татарстан: Док. и материалы (80–90-е гг.). К., 1999; Закиев М.З. Тюрко-татарское письмо: История, состояние, перспективы. К., 2005. *В.Х.Хаков.*

**«ЯҢАЛИ́Ф»**, татар язуын гарәп графикасыннан *яңалиф* латин графикасына күчерү тарафдарлары җәмгыяте. 1926 елда ТАССРның 6 нчы Советлар съездында оештырыла. Рәисе — Ф.Сәйфи-Казанлы. Әгъзалары — Г.Ш.Нугайбәк, Ш.К.Камал, И.Г.Рәмиев, М.Ә.Фазлуллин һ.б. Җәмгыятьнең максаты — «эшче-крәстияннәр арасында яңа татар алфавитын тарату». «Я.»нең үз нәшрияты була, һәм ул шул ук исемдә журнал чыгара. 1930 еллар башында эшчәнлеге туктала.

*Әд.:* Курбатов Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. К., 1999; Закиев М.З. Тюрко-татарское письмо (история, состояние, перспективы). К., 2005. *В.Х.Хаков.*

**«ЯҢАЛИ́Ф»**, Казандагы нәшрият. 1926 елда шул ук исемдәге җәмгыять каршында татар әдипләренең әсәрләрен латин хәрефләре б-н бастыру, дөнья һәм рус әдәбияты классикларының әсәрләренең тәрҗемәләрен әзерләү һәм нәшер итү максаты б-н оештырыла. Шул елда нәшрият 4 китап чыгара: Ф.Сәйфи-Казанлының «Яңа татар алфавиты», Г.Нугайбәкнең «Латинлаштыру факторлары», «Яңа татар әлифба графикасы», «Яңалиф уставы» проектлары. 1927 дә басмаларның төп өлешен язуны латинлаштыру принципларына багышланган җыентыклар, яңа алфавитны кертү буенча Г.Нугайбәкнең «Латин әлифбасы (яңалиф) һәм орфография нигезләре», Г.Хәбиби һәм Ф.Мөбарәкшинның «Яңалиф һәм яшьләр», Ф.Сәйфи-Казанлының «Ун сәгатьле иркле яңалиф курслары һәм авылда эшләү юллары», А.Н.Григорьевның «Керәшеннәр арасында яңа төрки алфавит мәсьәләләре» («Вопросы ново-тюркского алфавита среди кряшен») һ.б. гамәли кулланмалары тәшкил итә. Г.Нугайбәкнең латин графикасы нигезендәге беренче кыска «Әлифба»сы басыла. Яңа графика нигезендә татар телендә киң масса укучылар өчен китаплар нәшер итү башлана: Г.Тукайның «Яңа Кисекбаш», «Мияубикә», «Шүрәле», М.Гафуриның «Заятүләк һәм Сусылу» хикәяләре. Заман язучылары: Һ.Такташ, Х.Туфан, Г.Камал, Ш.Камал, М.Гали, Г.Гали, К.Нәҗми, Г.Кутуй, Г.Толымбай, Ш.Әхмәдиев, С.Сүнчәләй, Г.Коләхмәтов, Ф.Әмирхан, К.Тинчурин, Н.Исәнбәт, Т.Гыйззәт, Ш.Усманов, Г.Минский, Р.Ишморат, Л.Гыйльми, Т.Ченәкәй, Д.Юлтый, С.Атнагулов һ.б.ның бер томлык җыентыкларыннан торган «Татар язучылары әсәрләре» сериясе чыгарыла. Л.Н.Толстой, В.М.Гаршин, А.П.Чехов, М.Е.Салтыков-Щедрин, Н.В.Гоголь, Д.А.Фурманов, А.А.Блок, А.Н.Толстой, В.П.Катаев, Л.Н.Сәйфуллина, Ж.Б.Мольер, И.Ф.Шиллер, Г.Гейне, Дж.Лондон һ.б.ның әсәрләре басыла. Алар аша татар укучылары СССР һәм чит ил халыклары

әдәбияты б-н таныша. Басылган 198 китаптан 121 е — матур әдәбият әсәрләре, алардан бары тик дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре генә калыша. «Әлифба»лар арасында Ф. һәм С.Таһировлар, К.Әмири, Х.Кәриминең башлангыч мәктәп һәм олылар өчен мәктәпләргә исәпләнгән хезмәтләре бар. 1928 дән яңа графика нигезендәге китаплар *Татарстан китап нәшрияты* тарафыннан басыла башлый. 1931 дә «Яңалиф» ябыла.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Становление и развитие татарской советской книги: 1917–1932 гг. К.,1989

**«ЯҢАЛИ́Ф»**, *«Яңалиф»* җәмгыяте советының иҗтимагый-сәяси, әдәби рәсемле журналы. 1927 елның февраленнән 1930 ның маена кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 74 саны чыга. 1927 дә — ай саен, 1928 дән — аена 2 тапкыр, 1930 дан 3 тапкыр басыла. 1927–28 дә — латин һәм гарәп графикасы, 1929 дан бары латин графикасы гына кулланыла. Баш мөхәррире — «Яңалиф» җәмгыяте советы рәисе Ф.*Сәйфи-Казанлы*. «Я.» мөхәрририяте составына Г.Әлми, И.Рәми керә. Актив авторлары арасында — К.Әмири, С.Атнагулов, Х.Вәли, Х.Кәрим, Г.Нугайбәк, Ш.Мәхмүт, Ш.Усманов, М.Фазлуллин, Г.Хәбиб. Язмаларының күптөрле, рәсемле һәм аңлаешлы булуы б-н редакция Мәскәүнең «Огонёк» ж-лы стиленә ориентлаша. Төп темасы — «Яңалиф» җәмгыяте эшчәнлеген, дәүләт органнарының яңа алфавитны кертүгә кагылышлы хисап һәм карарларын яктырту, ш.и. «Яңалиф» ҮКның 3 нче пленумы турында (1929) мәгълүмат бирү һ.б. «Яңалифчеләр фронты» даими рубрикасында Татарстанда һәм аннан читтә латин язуын тарату б-н бәйле вакыйгалар яктыртыла. 1929 да редакция яңалифкә тизләтелгән күчешнең ярамаганын язып чыккан «*Сиксән икеләр хаты*»на тискәре фикерләр җыюны оештыра. Яңалифне популярлаштыру өчен журнал Г.Тукайның танылган әсәрләрен бастыра, «Иске мирас» рубрикасында Х.Сиражи, Җ.Руми, Г.Хәйям, Ш.Сәгъди әсәрләреннән өзекләр бирелә. «Я.» битләрендә Ә.Айдар, Н.Булат, Х.Кәримов, С.Кудаш, Ш.Маннур, К.Уразай, М.Халит, П.Хузангай, Ченәкәй һ.б. шигырьләре, Ә.Айдар, Ш.Маннур, Г.Хәбиб



«Яңалиф» журналы.

һ.б. прозасы басыла. Рус теленнән күп кенә тәрҗемәләрне А.Гомәр ясый. Журнал Казан тормышындагы зур вакыйгаларга («Эшче» операсы премьерасы, «Булат батыр» фильмы чыгу һ.б.) бәя бирә. «Библиография» бүлегендә яңалифтәге яңа китаплар, латин язуында яңа басма органнар турында кыскача мәкаләләр бирелә. Язмаларның күбесе эсперанто теленә багышлана. Яшьләр өчен рәсемле «Фән һәм техника» рубрикасы алып барыла. Редакция журналны алучыларга әдәби әсәрләр җыентыклары, ш.и. С.Борһанның «Үткәндәгеләр» китабын (1928) җибәрә.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ЯҢАЛИ́Ф»**, әдәби-нәфис, тәнкыйди-библиографик журнал. ТАССР Халык мәгарифе комис-ты һәм татар совет язучылары җәмгыяте органы. *«Безнең юл»* ж-лы дәвамчысы. 1930–32 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Ф.*Сәйфи-Казанлы*. Журналда әдәби әсәрләр, хәзерге татар әдәбиятына күзәтүләр дөнья күрә, әдәби процесс юнәлешләре һәм тенденцияләре анализлана. Әдәби-тәнкыйди һәм сәнгать белеме материаллары татар мәдәниятендәге әһәмиятле вакыйгаларга багышлана: Г.Айдарскийның «Театр реконструкция чорында» (1930, 2 нче сан), Г.Рәхимнең «Эшче» операсы турында» (1930, 3 нче сан) һ.б. А.Алиш, М.Әмир, И.Гази, М.Галәү, Ш.Камал хикәяләре, Х.Туфанның «Бибиевләр» (1930, 5–6 нчы саннар) поэмасы, А.Айдарның «Ташбай» (1931, 1–2 нче саннар) повесте, Ф.Хөснинең «Җир тыңлый» (1931, 4 нче сан) романы, Һ.Такташның «Киләчәккә хатлар» (1932, 4 нче сан), Ф.Кәримнең «Аникин» (1932, 7 нче сан) поэмалары, К.Тинчуринның «Кандыр буенда» (1932, 5 нче сан) пьесасыннан өзекләр һ.б. басыла. Ш.у.к. *«Казан утлары»*.

*Әд.:* М ә р д и е в а М. Рухи тормыш көзгесе // Тонус. 1996. № 1.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ЯҢАЛИ́Ф** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сулы елгасы (Димнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 7 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигезләнә. Оешкан көненнән — Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1938 дә — 251, 1949 да — 208, 1958 дә — 169, 1970 тә — 144, 1979 да — 104, 1989 да — 27, 2002 дә — даими яшәүче юк.

**«ЯҢАЛИ́Ф ГӘЗИТЕ́»**, атналык иҗтимагый-сәяси, фәнни, әдәби газета. *«Яңалиф»* җәмгыяте советы, соңрак — «Яңалиф» дәүләт ком-ты органы. 1928 елның 16 мартыннан 1929 ның 17 ноябренә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 85 саны чыга. Газета б-н составында Ф.*Сәйфи-Казанлы* («Яңалиф» җәмгыяте советы рәисе), З.Гыймранов («Яңалиф» җәмгыяте советы җаваплы сәркәтибе), С.*Борһан* булган мөхәрририят җитәкчелек итә; редакциядә ш.у. Ш.Фәхри, Х.Кәрим эшли. Актив авторлары арасында — К.Әмири, Н.Баян, Ә.Еники, Ф.Кәрим, Х.Кәрим, Г.Минский, Г.Хәбиб, М.Яхин. Башта газета «Яңалиф» җәмгыяте әгъзалары һәм яшь укучыларның мәнфәгатьләренә дә юнәлеш тота. Басманың төп темасы — «Яңалиф» җәмгыяте эшчәнлеге, дәүләт органнарының яңа алфавит кертү буенча карарлары, ш.и. ВКП(б) ның 14 нче партия конференциясе, «Яңалиф» һәм «Бетсен наданлык» җәмгыятьләре үзәк органнарының уртак пленумы резолюцияләре турындагы хисаплар һ.б. Татарстан һәм аннан читтә яңа алфавит тарату турында «Яңалифчеләр фронты» дигән даими сәхифәләр алып барыла. «Я.г.» Кырым, Әзәрбайҗан, Төркиядә һ.б.да латин язуына күчү, Укытучыларның белемен күтәрү ин-ты,


№10(48)
1929-jьl, 21 Mart

Janalif gəzite

JAŅALIF DƏVLƏT KƏMITITE URGЬNЬ

Janalif ike ajlьƣьnda, janalifcə uqьj-jaza belməgən keşe qalmasьn!

„Janalif" çəmƣijate

Pariƶ kammunasь

«Яңалиф» газетасы.

Шәрекъ пед. ин-тының татар бүлекләренә пед. кадрлар әзерләү турында хәбәр итә. Яшьләр өчен «Фән һәм техника» рубрикасы алып барыла, комсомол хәрәкәте турында материаллар урнаштырыла. 1928 нең 28 ноябрь (32) нче санында редакция укучыларга газетаның әдәби басма булачагын белдерә. А.Айдар, М.Җәлил, Г.Тләш, Д.Фәтхи шигырьләре, К.Әмири, Н.Баян, Ф.Кәрим һ.б. прозасы дөнья күрә. Әдәби-театраль һәм муз. күзәтүләр б-н Х.Вәли, Г.Нигъмәти, М.Парсин һ.б. чыгыш ясый. Газета яңалифтәге яңа китаплар, яңа алфавитка күчкән басма органнар турында мәгълүмат бирә. 1929 да редакция «Яңалиф» б-н «Бетсен наданлык» җәмгыятьләре кушылу һәм «Яңалиф» дәүләт ком-ты оешу сәбәпле, газета киң катлау эшче һәм крәстияннәр өчен чыгачагын, әдәби әсәрләр *«Яңалиф»* ж-лында басылачагын хәбәр итә. 1929 да ел дәвамында барлык татар матбугаты гарәп графикасыннан яңалифкә күчү б-н бәйле рәвештә, шул ук елның ноябрендә газета «Яңалиф» ж-лы б-н берләштерелә.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ЯҢАЛИ́Ф ПОХОДЫ́»**, газета; к.*«Азат Себер»*.

**«ЯҢАЛИФЧЕ́»**, журнал; к. *«Азат Себер»*.

**ЯҢАСАЛА́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 287 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигезләнә. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Енасала, Крещёные Янасалы исемнәре б-н дә билгеле. Халкы 1550–60 елларда чукындырыла, 1866 да күпчелеге яңадан ислам диненә кайта. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек, чана табаннары, тугым бөгү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Гурий чиркәве, мә-

чет, земство мәктәбе, 1 су һәм 2 җил тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1398,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 124 ир-ат; 1859 да — 621, 1908 дә — 1074, 1920 дә — 794, 1926 да — 823, 1938 дә — 894, 1949 да — 852, 1958 дә — 704, 1970 тә — 605, 1979 да — 496, 1989 да — 347, 2002 дә — 292 кеше. Я.да язучы Г.Б.Бәширов туган.

**ЯҢАСАЛА́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 37 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 274 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, кошчылык. Клуб, китапханә. Мәчет. Яңасала авылыннан күчеп килүчеләр тарафыннан нигезләнүе 19 йөзнең 1 нче яртысыннан да соң түгел. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, тимерче алачыгы, су тегермәне, 4 кибет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 688,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 12 гыйнварыннан — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 25 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1859 да — 185, 1897 дә — 647, 1908 дә — 830, 1920 дә — 629, 1926 да — 610, 1938 дә — 674, 1949 да — 681, 1958 дә — 657, 1970 тә — 711, 1989 да — 335, 2002 дә — 274 кеше.

**ЯҢАСАЛА́ СӨЗӘКЛЕГЕ́**, табигать истәлелеге. Арча р-ны терр-ясендә, Норма елгасы үзәнендә Яңасала авылыннан төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 1987 елда билгеләнә. Мәйданы 10 *га*. Урман зонасындагы 2 далаланган болын участогыннан тора. Сирәк үсемлекләрдән каурый кылган, язгы адонис һ.б. үсә. Объект фәнни-танып белү әһәмиятенә ия.



Яңасала сөзәклеге.

**ЯҢГУ́Л** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 1085 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1602–03 тән Елгулово буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә (лашман хезмәтен үти), җир эшкәртү, терлекчелек, сәүдә, Себер трактында йөк ташу б-н шөгыльләнә. 1773–75 тәге Крәстияннәр сугышында Е.И.Пугачёв ягында актив катнашалар. 20 йөз башында Я.да волость идарәсе, почта станциясе була; 3 мәчет (1838, 1882, 1894 тә төзелгән), мәктәп, су тегермәне, юлаучылар йорты, трактир, базар, берничә сәүдә кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4610 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Яңгул волосте үзәге, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1766 да — 288 ирт-ат; 1834 тә — 1268, 1859 да — 1935, 1884 тә — 2219, 1905 тә — 2379, 1920 дә — 2904, 1926 да — 2835, 1938 дә — 2501, 1949 да — 1659, 1958 дә — 1581, 1970 тә — 1582, 1979 да — 1043, 1989 да — 1096, 2002 дә — 1101 кеше. Я.да Сов. Сюзы Герое Г.Г.Гарифуллин туган.

**ЯҢГЫ́Р СУАЛЧАННАРЫ́**, туфрак суалчаннары зур туфрак олигохетлары семьялыгы төркеме. Таксономия берәмлеге вәкиле түгел. Морфологик билгеләре һәм тереклек үзенчәлекләре буенча билгеләнә. Якынча 1800 төре билгеле, Татарстан терр-ясендә Lumbricidae семьялыгыннан 14 төр билгеле. Гәүдәсенең озынлыгы 5–25 *см*, тарткылар б-н аерым бөҗра яки буыннарга бүленгән, затларның төре һәм яшенә нисбәттә аларның саны 80 нән 450 гә кадәр җитәргә мөмкин. Беренчесеннән кала, барлык буыннарның да аскы ягы берәр яки парлы урнашкан 8 төкчәле. Беренче буында баш калагы, аның астында авыз тишеме урнашкан. Күзләре юк, Я.с. яктылыкны фоторецепторлар — тиресендәге яктылыкка сизгер күзәнәкләр ярдәмендә сизә. Я.с. ике җенеслеләр. Олы затларның алгы өлешендәге сырты ягында берничә буынның юанайган бизле капламы — аталанганнан соң кузы барлыкка китерүче путачык бар, аларда яшь суалчаннар җитлегә. Путачыктан соң юкка чыккан гәүдә өлешләрен Я.с. яңадан үстерә ала (регенерациягә сәләтлеләр). Тире аша сулыйлар, кызыл канлы кан әйләнеше системасына ия. Тире күзәнәкләре Я.с.ын кибүдән һәм механик җәрәхәтләнүдән саклаучы лайла бүлеп чыгаралар. Төсе аксыл сорыдан карасу-көрән яки чиясыман кызылга кадәр. Я.с. өчен ике яшәү формасы хас — түшәлмәдә (урман түшәлмәсендә яки 1–1,5 *м* тирәнлектәге даими яшәү урыны — өннәрендә яшиләр; үсемлек калдыклары б-н тукланалар) һәм туфракта (60–80 *см* тирәнлектәге юллар ясап, һәрвакыт туфрак капламында яшиләр, туфрак кисәкчекләрен баш б-н этәреп яки эчәклек аша үткәреп хәрәкәтләнәләр; черемә б-н тукланалар). Җир өслегенә Я.с. төнлә, көндез — көчле яңгырлардан соң (исеме шуннан) чыгалар, бу вакытта туфракта дымлылык югары булганлыктан, күкертле водород концентрациясенең артуына китерүче микробиол. процесслар активлаша. Бөтен җирдә таралганнар. Аларның төр төрлелеге һәм саны аеруча тугай тибындагы болын һәм урман биоценозларында югары. Табигатьтә зур әһәмияткә ия: туфрак барлыкка килү процессында катнашалар (беренче булып Ч.Дарвин билгели), хайваннарның (кошлар, җир тычканнары, сукыр тычканнар, керпе, бурсык, кабан дуңгызы, аюларның) туклану рационына керәләр. Төрле авыру йоктыручы гельминтларны күчерүчеләр булырга мөмкиннәр; биогумус алу өчен, антропоген факторларның әйләнә-тирәлеккә тәэсирен бәяләү мониторингы системаларында кулланылалар.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 1; Алейникова М.М., Утробина Н.М. Животное население почв в агробиоценозах Среднего Поволжья // Животное население почв агробиоценозов и его изменение под влиянием сельскохозяйственного производства. К., 1969; Всеволодова-Перль Т.С. Дождевые черви фауны России: Кадастр и определитель. М., 1977.

*А.К.Жеребцов.*

**ЯҢГЫРАВЫ́К ОЗЫНБОРЫННА́Р** (Chironomidae), парканатлылар отрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. 10 меңгә якын төре билгеле, бөтен җирдә дә таралганнар. Россиянең Европа өлешендә 500 дән артык, Татарстан терр-ясендә якынча 150 төре бар. Chironomus, Procladius, Endochironomus, Glyptotendipes һ.б. ыруг вәкилләре киң таралганнар. Гәүдәсе 1 *мм* дан 1 *см* га кадәр. Ата зат анасыннан гәүдә формасы һәм кечерәк булуы, каурыйсыман куе мыекчалары б-н аерыла. Гадәттә, озынборыннар бер атнадан кимрәк яши. Сулык ярлары буенда тереклек итәләр. Олы затлар күпләп очканда (гадәттә, кич б-н), елга буйларында озынборыннар күченең яңгыравыклы нечкә тавышын ишетергә мөмкин (исеме шуннан). Я.о.ның индивидуаль үсеше өчен: күкәй, личинка, курчак, имаго (ярымҗитлеккән затлар) стадияләре хас. Соңгыларының төп бурычы — суга күкәй салу, гадәттә, 1–6 көннән алардан җитлеккән башлы, 3 күкрәк һәм 10 корсак буыннарыннан торган ачык кызыл, яшькелт яки башка төстәге личинкалар чыга. Грунт өслегеннән юка детрит җыеп тукланалар, ау ятьмәләре коралар, суны фильтрлыйлар. Алар ара-



С.Ж.Япиев.

сында ерткычлар бар. Личинкалары кабыгын берничә тапкыр сала һәм курчакка әверелә. Личинкалары 1 дән 12 айга кадәр, курчаклары 2–3 тәүлек яши. Личинкалары бентос б-н тукланучы балыкларның, су кошларының, су янында яшәүче имезүчеләр, ерткыч умырткасыз хайваннарның азыгы булып тора. Сулыкларның «үзеннән-үзе чистаруында», агымсуларны биол. чистартуда әһәмиятле роль уйныйлар. Сулыкларның пычрану индикаторы булып хезмәт итәләр. Othocladiinae ассемьялыгы личинкалары һәм Tanytarsini триблары — чиста, Chironomus ыругы личинкалары — уртача пычрак һәм бик пычрак сулыкларның индикаторы. Chironomus ыругы личинкалары (балык суалчаны — мотыль исеме б-н билгеле) балык тоту өчен җим һәм аквариум балыклары өчен азык булып тора. Гигант селәгәй бизләре булганлыктан, личинкалары генетик тикшеренүләрдә кулланыла.

*В.А.Яковлев.*

**ЯҢГЫРЧЫ́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 25 *км* төньяктарак, Арбор елгасы буенда. 2010 елда 18 кеше (удмуртлар) яши. 1619 дан Пустошь Енгурчинская буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да вак-төякләр кибете эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 424 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда, 1921 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1834 тә — 25, 1859 һәм 1884 тә — 166 шар, 1905 тә — 256, 1910 да — 218, 1920 дә — 243, 1926 да — 221, 1938 дә — 230, 1949 да — 150, 1958 һәм 1970 тә — 86 шар, 1979 да — 59, 1989 да — 30, 2002 дә — 16 кеше.

**ЯҢИ́Л** (Янил) авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 588 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Май з-ды. Урта мәктәп, аграр һөнәри белем көллияте, мәдәният йорты, китапханә. 1619 дан Анел авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новая Головина, Новая Семён Головина исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә (лашман хезмәтен үти), җир эшкәртү, терлекчелек, киез басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.дә Петропавел чиркәве (1907 дә төзелә), фельдшерлык пункты, тегермән, тимерче алачыгы, юлаучылар йорты, трактир, харчевня, 2 сырыханә, 1 казна шәраб һәм 7 вак-төякләр кибете була, шимбә базары эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1135,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Арча, 1928 дән — Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 179 ир-ат; 1859 да — 655, 1897 дә — 835, 1908 дә — 977, 1920 дә — 979, 1926 да — 1019, 1938 дә — 1081, 1949 да — 813, 1958 дә — 727, 1970 тә — 642, 1979 да — 621, 1989 да — 639, 2002 дә — 392 кеше.

**Я́О** Любовь Маркеловна (17.8.1950, Казан), социолог, филос. фән. канд. (1987), социол. фән. д-ры (2005), проф. (2008), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1978 елдан Казан пед. ин-тында. 1988 дән СССР Авиация сәнәгате министрлыгының квалификация күтәрү ин-тында. 1992 дән Казан техник ун-тының дәүләт, муниципаль идарә һәм социол. кафедрасында. Хезмәтләре җәмгатьчелек фикере теориясе һәм практикасына, экологик аң феноменына, Россия җәмгыятендәге социомәдәни процессларга карый.

Х е з м.: Социокультурные факторы формирования экологического сознания. К., 2002; Экологическое сознание современного российского общества: теоретико-методологические подходы. М., 2004.

**ЯПАНЧА́** (? — 1552), Казан морзасы, татар атлы гаскәре башлыгы. 1552 елда Иван IV гаскәрләре Казанны камап торганда (к. *Казанның яулап алынуы*) Я. ның отряды рус гаскәрләренең тылында хәрәкәт итеп, шәһәрне яклаучыларның дошманга каршы һөҗүмнәренә булышлык итә. 30 августта А.Б.Горбатый-Шуйский җитәкчелегендәге рус гаскәрләре Я. *га* каршы чыга һәм аның атлы гаскәрен җиңә. Я. Арчага чигенеп көч туплый һәм русларга кабат һөҗүм ясый. 6–8 сентябрьдә руслар Я. отрядын тулысынча тар-мар итеп, Арчаны штурмлыйлар һәм яулап алалар, сугыш вакытында Я. һәлак була.

*Әд.:* Х у д я к о в М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; А л и ш е в С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV — XVI вв. К., 1995.

**ЯПАНЧЫ́** (Ябынчы) авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 16 *км* көньяктарак, Шәмәк елгасы буенда. 2010 елда 5 кеше (татарлар) яши. Казан ханлыгы чорында нигезләнә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек, читкә китеп эшләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да мәчет, тимерче алачыгы, су һәм җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 936,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 81 ир-ат; 1859 да — 346, 1897 дә — 530, 1908 дә — 607, 1920 дә — 552, 1926 да — 619, 1938 дә — 751, 1949 да — 399, 1958 дә — 280, 1970 тә — 218, 1979 да — 162, 1989 да — 28, 2002 дә — 12 кеше. Я.да галим, философ, дин белгече Ш.Мәрҗани туган.

**ЯПИ́ЕВ** Асылгәрәй Солтангәрәй улы (26.8.1929, Мөслим р-ны Мари Бүләр а. — 17.5.2011, Актаныш р-ны Мари Суыксуы а.), стоматолог, мед. фән. д-ры (1993), проф. (1994). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Мари АССРның Йошкар-Ола шәһәре стомат. поликлиникасында эшли. 1964–80 елларда Казан мед. ин-тының терапевтик стомат. кафедрасында, 1979 дан шул ук каф. доценты. 1981–83 тә Ижевск мед. ин-тының стомат. курсы мөдире. 1983 тә терапевтик стомат. кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире. Хезмәтләре тешләрнең сульфат кислотасы б-н зарарлану клиникасын өйрәнүгә, авыруны кисәтү һәм дәвалау ысулларын эшләүгә карый.

Х е з м.: Кислотный некроз зубов. М., 1974 (автордаш); Клинические и лабораторные методы обследования больного и терапевтической стоматологии. Ижевск, 2004 (автордаш); Диагностика в терапевтической стоматологии. Ростов н/Д., 2005 (автордаш).

*Әд.:* А.С.Япеев: Жизнь в науке. Ижевск, 2009.

**ЯПИ́ЕВ** Салих Җәләлетдин улы (17.9.1914, Чиләбе ш. — 20.12.1993, Казан), эчке эшләр органнары генерал-лейтенанты (1967).Чиләбе коммуналь-төзелеш техникумын (1934), кече командирлар составы мәктәбен (Чиләбе, 1937), Казан ун-тының юридик ф-тын (1952) тәмамлый. 1936–38 елларда Чиләбедәге 85 нче укчы дивизиянең аерым элемтә батальонында рота политругы урынбасары. 1938–41 дә Чиләбе водоканал трестында прораб һәм төзелеш секторы башлыгы. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында: 23 нче укчы дивизиянең 89 нчы укчы полкында автоматчылар ротасы политругы, 117 нче укчы полкта сәяси бүлек командиры урынбасары. Балтыйк буе, Төньяк-Көнбатыш, Сталинград фронтлары гаскәрләре составында Каунастан көнбатыштарак оборона сугышларында (1941), дошманның Демянск төркемен камап алуда (1942), Сталинград янындагы (1942–43), Курск дугасындагы (1943) сугышларда, Белоруссия һөҗүм операциясендә (1944) катнаша. 1946 да демобилизацияләнә. Эчке эшләр министрлыгының 8 нче Казан киносатма ф-касы каршындагы хәрбиләштерелгән янгын саклау бүлегендә сәяси бүлек башлыгы урынбасары. 1947–78 дә ТАССР Эчке эшләр министрлыгында: Хәрби әсирләр лагере идарәсендә (Алабуга ш.) сәяси бүлек башлыгы урынбасары, 1948–50 дә партком секретаре, 1953–54 тә Эчке эшләр министрлыгының Чистай р-ны идарәсе башлыгы урынбасары, Милиция идарәсендә сәяси бүлек башлыгы. 1954–78 дә ТАССР эчке эшләр министры. Бу чорда «халык дружиналары» оештырыла һәм киң тарала, шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә милиция җәмгать пунктлары ачы-

ла, участок уполномоченныйлары эше җайга салына, җинаятьчелек һәм вак тәртип бозулар саны күпкә кими, Эчке эшләр министрлыгы органнарында милли кадрлар, «Динамо» спорт җәмгыяте үсеш ала. 1978–84 тә СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясенең Казан бүлеге башлыгы. 1955–80 дә ТАССР ЮС депутаты. Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казанның бер урамы Я. исемен йөртә.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЯППА́РОВ** (Җаббаров) Илдар Әхтәм улы (22.6.1974, Казан), зоотехник, а.х. фән. канд. (2006), биол. фән. д-ры (2014). ТР Дәүләт бүләге лайреаты (2014). Казан вет. медицинасы академиясен тәмамлаганнан соң (1996), «Раифа» җәнлек с-зында (Яшел Үзән р-ны) баш зоотехник, директор урынбасары. 1999–2002 елларда «Болак» ЯАҖ директоры. 2003–04 тә Казан уксус з-дында. 2004–05 тә «Плодородие» ҖЧҖдә техник директор. 2005 тән Россия а.х. академиясенең Татарстан агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-тында: терлекчелек бүлегендә өлкән фәнни хезмәткәр, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, 2010 нан игенчелек һәм терлекчелектә биоһәм нанотехнологияләр эшләү бүлеге мөдире, 2016 дан вакытлыча директор вазифаларын башкаручы, 2018 дән директор. Хезмәтләре селенорганик препаратлар һәм җирле табигый минераллар нигезендә өстәмә азыклар эшләү һәм аларны терлекләр һәм а.х. кошларының продуктлылыгын күтәрү, сыйфатын яхшырту өчен куллануга карый. Уйлап табуга 32 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Агроэкологические аспекты комплексного использования местных сырьевых ресурсов и нетрадиционных агроруд в сельском хозяйстве. К. 2007 (автордаш); Технология использования кормовой добавки селебни, биологическая и физиологическая оценка влияния его на продуктивность животных. К. 2010; Использование сорбентов в рекультивации нефтезагрязненной почвы при выращивании Vicia Sativa L. // Достижения науки и техники АПК. 2017 (автордаш).

**ЯППА́РОВА** Роза Сәетнур кызы (2.1.1949, Баулы р-ны Хансуәр а.), мәдәният эшлеклесе, ТРның һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1997, 2004). Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1971–72, 1977–79 елларда газета редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, баш мөхәррир урынбасары, 1972–77 дә Бөгелмә урта мәктәбендә укытучы. 1979 дан Казанда Татар «Әкият» курчак театрында – педагог-оештыручы, әдәби бүлек мөдире, 1993 тән театрның директоры. Курчак театры сәнгатен популярлаштыруга, тамашачы б-н пед. эшчәнлек алып баруга, коллективта иҗади атмосфера тудыруга зур игътибар бирә. Я. театрның заманча эшләнгән яңа бинасын булдыруда башлап йөрүче. Аның җитәкчелегендә театр халыкара курчак театрлары фестивальләрендә катнаша, илебез шәһәрләренә гастрольләр б-н чыга. Я. РФ Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1983). Халыкара курчак театрлары эшлеклеләре оешмасының персональ әгъзасы (1996). Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Балачак ул курчаклы булырга тиеш // Сәхнә. 2014. № 9; К должностям и статусу женщины стремятся не ради власти, а ради миссии // Татарстан. 2017. № 3; Развивая воспитывать // Элита Татарстана. 2018. № 3.

**ЯР БУЕ́ МОРКВАШЫ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 20 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2010 елда 594 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар – 41%, руслар – 36%) яши. Халкының төп шөгыле – кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигезләнә. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпвыт (элекке экономик, 1764 кә кадәр монастырь) крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек, балта эшләре, тегүчелек, таш чыгару б-н шөгыльләнә, елга транспортында хезмәт күрсәтә. 1860 елларда Я.Б.М.нда алпавыт Тиленең шәраб з-ды эшли. 20 йөз башында земство мәктәбе (1867 дән булган чиркәү-приход мәктәбе нигезендә 1870 тә ачыла), язуга өйрәтү мәктәбе (1899 да ачыла), «М.Корольков һәм А.Баранов уллары белән» сәүдә йортының пар тегермәне, 1 камыр ризыклары һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 327 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Югары Ослан волостенда, 1920 дән – ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән – Зөя, 1931 нең 20 октябреннән – Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән – Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә – 103 ир-ат; 1859 да – 266, 1897 дә – 281, 1908 дә – 300, 1920 дә – 477, 1926 да – 278, 1938 дә – 452, 1949 да – 640, 1958 дә – 725, 1970 тә – 480, 1979 да – 465, 1989 да – 561, 2002 дә – 530 кеше.

**ЯРА́К-ЧУРМА́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шушманың сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 144 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле – дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында Зур Лызи авылыннан күчеп килүчеләр нигезли. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Починок Ярак Чурма исеме б-н дә билгеле. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек, кортчылык, балыкчылык, аучылык, киез итекләр басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1890 да ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 371,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан – Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан – Балтач, 1963 нең 1 февраленнән – Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1834 тә – 81, 1859 да – 87, 1876 да – 110, 1897 дә – 146, 1908 дә – 154, 1920 дә – 149, 1926 да – 180, 1938 дә – 233, 1949 да – 203, 1958 дә – 188, 1970 тә – 197, 1979 да – 133, 1989 да – 141, 2002 дә – 139 кеше.

**ЯРА́Н** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Иләт елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 24,2 *км*, ТР чикләрендә – 4 *км*. Бассейнының мәйданы 99,5 *км*². Вятка Увалы калкулыгыннан ага. Елга башы Мари Респ-касы терр-ясендә, тамагы Биектау р-ны Шөмләнь авылыннан 2 *км* төньяктарак, урман массивында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы – 85 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. Я.ның 0,7 дән 2,5 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана, Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,17 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**ЯРА́Н**, я р а н г ө л (Geranium), яранчалар семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 400 гә якын төре билгеле, башлыча, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә 8 төре бар. Болын Я.ы (G. pratense), урман Я.ы (G. sylvaticum), сазлык Я.ы (G. palustre), кызыл Я. (G. sanguineum) респ-каның бөтен җирендә таралганнар, Роберт Я.ы (G. robertianum) Идел алдында очрый, Себер Я.ы (G. sibiricum) – Идел алдында һәм Кама арьягында. Урманнарда, урман буйларында, болын, аланнарда үсә. Кечкенә Я. (G. pusillum) – рудераль үсемлек.



Роберт яраны.

10–80 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, өске өлеше ботаклы. Яфраклары бармаксыман бүленмә, ара-тирә каурыйсыман, төпчек яфраклы. Чәчәкләре ачык төстә, берле яки куентылы чатырларда. Җимеше – томшыксыман озын тартмачык, өлгергәч орлыклы биш өлешкә ачыла һәм орлыклары тышкы тирәлеккә коела. Июньнән сентябрьгә кадәр чәчәк аталар. Җимешләре июль-сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм ботаклардан үрчиләр. Урман Я.ы, болын Я.ы, кызыл Я. – дару үсемлекләре, дуплау матдәләренә ия, баллы үсемлекләр. Кайбер төрләрен декоратив үсемлек буларак үстерәләр.

**ЯРӘ́П** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 15 *км* көньяктарак, Борнай елгасы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 18 йөздә нигезләнә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Иштыбай исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.тә Троица чиркәве, Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1898 дә ачыла), 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире

2702 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Әлки волостенда. 1920 дән — ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1865 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 566, 1897 дә — 892, 1908 дә — 815, 1920 дә — 878, 1926 да — 526, 1938 дә — 356, 1949 да — 303, 1958 дә — 378, 1970 тә — 211, 1979 да — 135, 1989 да — 27, 2002 дә — 7 кеше (чуашлар, руслар).

**ЯРӘ́П** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 8 *км* көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 285 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1794 тән билгеле. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.тә Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1898 дә ачыла), вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1252 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1859 да — 303, 1897 дә — 544, 1908 дә — 562, 1920 дә — 665, 1926 да — 630, 1938 дә — 399, 1949 да — 364, 1958 дә — 369, 1970 тә — 478, 1979 да — 432, 1989 да — 302, 2002 дә — 303 кеше.

**«ЯРДӘ́М»**, Семипалатинск шәһәрендәге басмаханә. 1911 елда бертуган Садыйк, Солтан һәм Хәсән Нигъмәтуллиннар тарафыннан ачыла. Әлеге басмаханәдә басылган 19300 данәлек гомуми тираж б-н 12 басма билгеле. Башлыча, казакъ телендәге китаплар чыга, алар арасында — казакъ шагыйрьләре Т.Жомартбаев, Ш.Кудайбердиевның шигырьләр җыентыклары, М.Малдыбаев әсәрләре, ш.у. татар телендә Рәүф, Г.Мусин, Я.Айманов җыентыклары, 1916 елгы «Сибирия календаре» һ.б. китаплар. 1916 да басмаханә казакъ Укибаевка сатыла.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

*Г.Г.Габделганиева.*

**ЯРДӘ́М** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 38 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 7 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 51 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1926 да нигезләнә. Оешкан көнненнән ТАССРның Спас кантонында, 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1938 дә — 190, 1949 да — 167, 1958 дә — 160, 1970 тә — 190, 1979 да — 143, 1989 да — 64, 2002 дә — 62 кеше.

**ЯРДӘ́М**, к. *Өмә.*

**ЯРДӘМЛЕ́К СҮЗЛӘ́Р**, лексик яктан мөстәкыйль булмаган сүзләр; сүзләр, җөмләләр, җөмлә кисәкләре арасында төрле семантик-синтаксик мөнәсәбәтләр, ш.у. модаль мәгънәләр белдерү өчен кулланылалар. Лексик һәм грамматик берәмлек буларак, Я.с. мөстәкыйль сүзләргә капма-каршы куела. Я.с. атау функциясен башкармый, ягъни мөстәкыйль сүзләрдән аермалы буларак, предметны, билгене, эш-хәлне белдерми. Я.с.нең мөстәкыйль сүзләрдән аермасы шунда — алар, грамматик берәмлек буларак, морфологик категорияләргә ия түгел һәм синтаксик конструкцияләрдә бары тик ярдәмче функцияләр генә башкаралар. Татар телендә, башкарган функциясеннән чыгып, бәйлек һәм бәйлек сүзләрләрне, *теркәгеч* һәм теркәгеч сүзләрне, *кисәкчәләрне* Я.с.гә кертеп карыйлар.

*Әд.:* Татар грамматикасы. Морфология К., 2016. Т. 2; Лингвистик терминнарның русча-татарча аңлатмалы сүзлеге=Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов. К., 2016.

**ЯРДӘМЧЕ́ АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́**, туклану продуктларына кытлыкны каплау һәм аларны куллануны коллективларда тулырак канәгатьләндерү (үз ашханәләрен, яслеләр һәм балалар бакчаларын, ял итү базаларын һәм йортларын, үз эшчеләренә сатуны тәэмин итү) өчен а.х. продукциясен җитештерү максатында оештырылган пр-тиеләр, оешмалар, учреждениеләрнең бүлекчәсе. Беренче Я.а.х. Бөек Ватан сугышы елларында барлыкка килә; алар яңадан 1970–80 елларда торгызыла башлыйлар. Я.а.х. мөстәкыйль (юридик зат хокукы бирелгән) яисә пр-тиеләр, оешмалар, учреждениеләрнең структур бүлекчәсе була ала. Я.а.х.н матди-техник яктан тәэмин итү, машиналар, җиһазларны ремонтлау һәм техник ярдәм күрсәтү пр-тие һәм оешмаларның үзләре тарафыннан башкарыла. Бу хуҗалыкларга а.х. продукциясен сатуга дәүләт планы билгеләнми. Җәмәгать туклануы пр-тиеләренә һ.б. ихтыяҗларга ярдәмче хуҗалыклардан ит, сөт, бәрәңге, яшелчә җибәрү тәртибе КПСС ҮК һәм СССР МСның 1978 елның 4 декабрендә кабул ителгән «Предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрнең ярдәмче авыл хуҗалыклары үсеше» карары нигезендә билгеләнә. Алар хезмәт коллективларына дәүләт ваклап сату бәяләрендә һәм совхозларга каралган шартларда сатыла. Я.а.х. Татарстанның барлык эре пр-тиеләрендә эшли, аларны директорлар (идарәчеләр) җитәкли. 1999 ел башына Татарстанда 200 дән артык Я.а.х. исәпләнә. Алар җитештерү-хуҗалык планнары буенча, хуҗалык исәбе принципларына нигезләнеп (пр-тие, оешма, учреждение тарафыннан аларга тапшырылган хокук кысаларында) эшчәнлек алып бара. Базар мөнәсәбәтләренә күчкәч, Я.а.х.лары яшәүдән туктыйлар, мөстәкыйльлек алалар, хуҗалык исәбе принципларына нигезләнеп, инвесторларга тапшырылалар.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ЯРКӘ́ЕВ** (Яркалов) Хөснулла Хәбибнаҗар улы (28.12.1920, БАССРның Гафури р-ны Игеньелга а. — 1972, Дүшәнбе, Таҗикстан Респ-касы), Дан орденының тулы кавалеры (16.9.1944, 30.11.1944, 29.6.1945), гв. өлкән сержанты. Чарҗау (Төрекмәнстан ССР) шәһәрендә слесарь-ремонтчы булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында: 45 *мм* лы туп батареясы туп командиры, 133 нче гв. укчы полкының (1 нче удар һәм 65 нче армияләрнең 44 нче гв. укчы дивизиясе) танкка каршы туп батареясында взвод командиры. 2 нче һәм 3 нче Балтыйк буе, 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Тарту, Рига (икесе дә 1944 тә), Млава-Эльбинг (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең августында Валга шәһәре (Эстония ССР) янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: туп расчёты б-н туры төбәп, дошманның 2 пулемётын юк итә һәм пехотага дошман оборонасына үтеп керергә мөмкинлек тудыра; 1944 нең 6–7 октябрендә Сигулда (Латвия ССР) шәһәре янындагы сугышларда туп расчётлары б-н пехота арасында урнаштырылган хәлдә дошманның танкын сафтан чыгара, 6 пулемёт ноктасын бастыра, 20 ләп солдатын юк итә; 1945 нең 14–18 гыйнварында Сероцк (Польша) шәһәреннән төньяк-көнбатыштарак барган сугышларда 5 пулемёт ноктасын бастыра, дошманның йөкле 2 автомашинасын сафтан чыгара һәм 1 отделениедән күбрәк солдатын юк итә, яралана, ләкин сугыш кырыннан китми. Демобилизацияләнгәннән соң (1947), Ашхабад, 1949 дан Сталинабад (хәзер Дүшәнбе) шәһәрләрендә яши. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Х.Х.Яркәев.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЯРКӘ́ЕВА** Фәридә Фатих кызы (6.10.1961, Баулы пос.), фармацевт, фарм. фән. д-ры (2010), ТРның атказ. сәламәтлек саклау хезмәткәре (2002). Казан. мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1985), Казанда хәрби часть даруханәсе мөдире булып эшли. 1990–98 елларда «Татарстанфармация» дәүләт пр-тиесе ген. директоры урынбасары. 1998–2001 дә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Фармация департаменты башлыгы урынбасары. 2001–06 да ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация идарәсе башлыгы, 2006 дан ТР Сәламәтлек саклау министры урынбасары. Хезмәтләре формуляр системасын оптимальләштерү өлкәсенә, ТРда дарулар б-н тәэмин ителеш торышына карый. «Донор каны һәм кан компонентларының югары сыйфатлы сакланышын тәэмин итәргә сәләтле яңа буын суыту техникасы эшләү һәм дәвалау эшчәнлегендә гамәлгә кертү» хезмәте өчен ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә лаек була (2006). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Выбор основных лекарственных средств в региональной лекарственной политике // Казан. мед. журн. 2008. № 4.

**ЯРКӘ́Ү РАЙОНЫ́**, *Түмән өлкәсенең* көнбатышында урнашкан. 1925 елда оештырыла. Мәйданы — 6656 *км*². Үзәге — Яркәү авылы (Түмән шәһәреннән 94 *км* ераклыкта). Хал-

ки — 23324 кеше (2017). Татарлар саны: 1959 да — 8232, 1979 да — 8929, 1989 да — 8003, 2002 дә — 8265, 2010 да — 7538 кеше. Алар, тупланып, Рәгез(Кугалы, Рус Матмасы), Яңа Кәешкүл, Сәет, Чичикә (Чечкино), Бехтери, Олы Кызылъяр, Бурбар (Варвара), Аккүл (Дулепино), Еманаул, Карбан (Кызылкаш), Кортъегән (Куртюганы), Носык (Малое Чечкино), Уба (Малый Эсаул), Түре (Мотуши), Ваңгы (Новонерда), Иске Кәешкүл, Тәүде (Сакандыкова), Тархан, Шатан авылларында яшиләр. 1930 еллар башында районда 12 татар-башкорт мәктәбе исәпләнелә, 1962 дә 17 мәктәптә укыту татар телендә алып барыла. Хәзерге вакытта районның 6 мәктәбендә татар теле — фән буларак, 8 ендә факультатив дәресләрдә укытыла. Ел саен Яңа Кәешкүл урта мәктәбе җирлегендә туган телне өйрәнү мәсьәләләре буенча семинар уздырыла. 2005–08 дә район балалар китапханәсендә «Дуслык» клубы, ш.у. Я.р. татарларының милли-мәдәни автономиясе (1998 дән), «Ләйлә» фольклор коллективы (Шатан а., 1993 тән), «Чулпан» ансамбле (Түре а., 1998 дән), «Ялкын» балалар фольклор төркеме (Карбан а.) эшли. Районда ел саен «Таң йолдызы» балалар халык иҗаты фестивале, *Сабан туе*, Әмәл (Себер татарларында яз бәйрәме), Йомырка бәйрәме (Яңа Кәешкүл а.) үткәрелә. Бурбар, Яңа Кәешкүл, Яркәү, Чичикә, Карбан, Кызылъяр, Кортъегән, Түре, Ваңгы, Шатан авылларында мәчетләр эшли. Я.р. терр-ясендә шәех Даут каберлек-астанәсе саклана. Сов. Союзы Геройлары Ә.М.*Кәлиев* (Тархан а.) һәм Х.Ә.*Ниятбәковның* (Карбан а.) тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Я.р. б-н бәйле.

**«ЯРЛЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Кузнецк губерна ком-ты мөселман эшләре бүлеге органы. 1918 елның 26 апреленнән Саратов, Кузнецк (Саратов губ.) шәһәрләрендә нәшер ителә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

**ЯРЛЫ́ КӘРИ́М** (тәхәллүсе, чын исеме һәм фамилиясе Кәримов Габдулла Әхмәтвәли улы) (1901, Уфа губ., Бәләбәй өязе Ает а. – 1937, Уфа), шагыйрь. Ф.*Кәримнең* абыйсы. 1917 елга кадәр авыл мәдрәсәсендә, аннан соң «Хөсәения» мәдрәсәсендә (Уфа) укый. Гражданнар сугышында катнаша. 1921–22 дә Көнчыгыш хезмәт ияләре коммунистик ун-тында укый (Мәскәү). 1926 га кадәр партия эшендә. Я.К.нең Казан, Уфа, Мәскәү вакытлы матбугатында басылган шигырьләре искелеккә, рев-ция дошманнарына каршы хисләр б-н сугарылган; аларда илдәге социаль үзгәрешләргә дан җырлана. Кайбер шигырьләре «Татар поэзиясе анталогиясе»нә (1957) кертелгән.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**«ЯРЛЫ́ ХАЛЫ́К»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1918 елда Петроградта татар телендә нәшер ителә. Газетаны 1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң ук баса башлау планлаштырыла, әмма Петроград мөселман җәмәгатьчелеге ягыннан ярдәм булмаганга, ният гамәлгә ашырылмый. Беренче саны 1918 нең 6 гыйнварында басыла, барысы 2 саны чыга. Нашире — Милләтләр эшләре комис-ты, мөхәррирләре — К.*Мотыйгый*, Г.Гыйззәтуллин. Газета битләрендә совет хөкүмәтенең беренче декретлары, илдәге сәяси вазгыять турындагы мәкаләләр урын ала. Кызыклы язмалар арасында — большевикларның мөселманнарга Коръәннең Эрмитажда саклана торган борынгы басмасын тапшыруы турындагы хәбәр. Газета чыгудан туктагач, укучыларга «*Чулпан*» г-тасын җибәрә башлыйлар.

**ЯРЛЫ́К**, Монгол империясе, Алтын Урда, Казан, Кырым, Әстерхан ханнары тарафыннан чыгарылган фәрман-әмер характерындагы документ (фәрман, боерык, әмер). «Я.» терминының «хан фәрманы» буларак формалашуы 10 йөздән дә соң түгел, әмма ул Монгол империясе оешу чорыннан киң тарала башлый (13 йөзнең 1 нче яртысы). Монгол ханнарының беренче Я.лары телдән тапшырыла. Соңрак язма Я.лар барлыкка килә, әлеге традиция уйгырларга барып тоташа (10–11 йөзләрдәге уйгыр бәкләренең Я.лары билгеле). Монгол империясендә Я.лар төрле провинцияләрдә идарәче билгеләү яки вассал идарәчеләрне тану уңае б-н чыгарыла. Алтын Урда Я.лары турындагы беренче искә алулар 1250 елларга карый. Алтын Урда Я.лары арасында вассалларга юлланган әмер Я.лар, ярлыкау Я.лары бар. Тарханлык (мәхкәмә, ясак-салым иммунитеты), сөйургаллык (җиргә милекчелек), хезмәт (вазифага билгеләү, кенәзлеккә хокук, бәклек, идарә һ.б.), ташламалы (аерым салымнардан һәм йөкләмәләрдән азат итү; нинди дә булса өстенлекләрне раслау), саклау (дипломатларның, сәүдәгәрләрнең кагылгысызлыгын тәэмин итү; ерак җирләргә баручыларга бирелә), аренда (казна пр-тиеләре, мәс., акча сугу йорты б-н идарә итү) Я.ларына һ.б.га бүленә. 1267, 1332, 1342, 1347, 1357, 1358, 1379 да Алтын Урда ханнары *Мәңгү Тимер*, *Үзбәк*, *Җанибәк*, *Бирдебәк*, *Мөхәммәдбуләк* Я.ларны рус руханиларына, Азак шәһәрендәге Венеция сәүдәгәрләренә бирәләр. Чыганакларда рус кенәзләренә дә кенәзлек итү өчен Я.лар бирелүе искә алына. Алтын Урда таркалганнан соң, татар ханнары Я.лар бирү традициясен дәвам итә. Казан ханнары *Ибраһим* һәм *Сәхибгәрәйнең* (к. *Сәхибгәрәй хан ярлыгы*) ике тарханлык Я.гы; Кырым ханнарының берничә йөз Я.гы (15–18 йөзләр) билгеле. Я. текстына түбәндәге элементлар керә: инвокация (Аллаһны зурлау), интитуляция (документның бирүченең исемен күрсәтү); инскрипция (Я. бирелгән затны күрсәтү), промульгация (рәсми белдерү, мәс., «Йола буенча белегез» сүзләре), наррация (эш-хәлне бәян итү), диспозиция (үтәлергә тиешле күрсәтмәләр), санкция (тыюлар, күрсәтмәләрне үтәмәгән очракта күреләчәк чаралар), таныклык билгесе (мөһер), Я. язылу вакыты һәм бирелү урыны, мөрәҗәгать итүчеләр, язучылар, текстны төзүчеләр турында мәгълүмат. Текст бер яки берничә бит кәгазьгә кара төстәге кара б-н (аерым фрагментлар алтын яки кызыл кара б-н аерымлана) языла; расланган документ текстның ахырыннан башына таба төрелә. Я.лар татар ханлыкларындагы җәмгыять корылышы, адм. һәм салым системасы, эш кәгазьләре, язу традициясе тарихы, әдәби тел турында бай материалга ия.

*Әд.:* Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева улуса XIV–XVI вв. К., 1979; Григорьев А.П. Сборник ханских ярлыков русским митрополитам: Источниковедческий анализ золотоордынских документов. СПб., 2004; Почекаев Р.Ю. Право Золотой Орды. К., 2009.

**ЯРЛЫЛА́Р КОМИТЕТЫ́**, авыл ярлылары оешмасы, авылда совет хакимиятенең төп терәк пункты. 1918 елның 2 нче яртысында — 1919 ел башында Россиянең Европа өлешендә һәм Белоруссиядә гамәлдә була. Авыл ярлыларының мөстәкыйль оешмасы барлыкка килү хосусый хуҗалык җирләрен һәм милекне бүлешү процессында сәяси көрәшнең кискенләшүе, 1918 нең кыш-яз айларында азык-төлек кризисы б-н бәйле. Я.к. оештырурга совет хакимиятенең «Икмәк запасын яшерүче һәм аның белән спекуляция ясаучы авыл буржуазиясенә каршы көрәштә Азык-төлек халык комиссариатына гадәттән тыш вәкаләтләр бирү» (1918 ел 9 май), «Авыл ярлыларын оештыру һәм тәэмин итү турында» (1918 ел 11 июнь) декретлары этәргеч бирә. Декретларның соңгысы нигезендә җирле советлар волость һәм авыл Я.к.лары оештыра. Анда «кулаклардан һәм байлардан» башка авыл халкы сайлана һәм сайлый ала. Урта хәллеләр, кагыйдә буларак, катнаштырылмый. Я.к. эшчәнлегенә икмәк, беренчел көнкүреш кирәк-яраклары, а.х. кораллары өләшү; крәстияннәрнең башка өлешеннән, беренче чиратта кулаклардан икмәк тартып алуда азык-төлек органнарына ярдәм күрсәтү керә. Ком-тлар җирле партия структуралары, азык-төлек һәм җыю-реквизиция отрядларының басымы нигезендә оештырыла, аларны, гадәттә, коммунистлар җитәкли. 1918 нең ноябренә Россиянең Европа өлешендә һәм Белоруссиядә 122 мең, ш.и. Казан губернасында 3350 Я.к. төзелә.

Казан губернасының күп өязләрендә Я.к., хакимиятне үз кулларында туплап, авыл һәм волость советларында кабат сайлаулар үткәрә яки аларны тарата. Икмәк һәм чимал әзерләү б-н шөгыльләнә, сәнәгать шәһәрләрен, Кызыл Армияне һәм ярлыларны азык-төлек б-н тәэмин итә. Волость һәм авыл Я.к.лары азык-төлек отрядлары б-н бергә крәстияннәр җыйган икмәкнең исәбен ала, тентү үткәрә, авыл кешеләреннән тартып алынган икмәкнең, терлекнең һәм мөлкәтнең хисабын төзи, юлларда, елга портларында, тимер юл станцияләрендә икмәк озатуга күзәтчелек итә, «капчыкчылар»га (вак сәүдә б-н шөгыльләнүчеләр), спекуляциягә каршы көрәшә, тегермәннәрдә он тартуга контроль урнаштыра. Хосусый милектәге тегермәннәр еш кына конфискацияләнә һәм җәмәгать милке дип игълан ителә. Ком-тлар эшчәнлеге нәтиҗәсендә Казан губернасыннан Мәскәүгә һәм Петроградка икмәк озату күләме кискен арта. 1918 нең июленә кадәр 19237 пот икмәк озатылса, 12 сентябрьдән 12 октябрьгә кадәр — кайбер өязләрнең Чех-словак корпусы һәм Комучның Халык армиясе оккупациясендә булуына карамастан — 400 пот, ноябрь-

гә 1 млн. поттан артык икмәк җибәрелә. 1918 нең августыннан 1919 ның мартына кадәр Казан губернасыннан барлыгы якынча 5,7 млн. пот чамасы ашлык һәм азык-төлек, ш.и. 2,7 млн. пот арыш һәм бодай, 2,5 млн. поттан артык солы һәм арпа, 509 мең поттан артык төрле ярмалар һәм кузаклылар озатыла. Я.к. сәнәгать товарларын өләшү б-н дә шөгыльләнә. 1918 нең октябрь–декабрь айларында авыл өчен якынча 6,3 млн. аршын мануфактура, 166 мең поттан артык керосин, 32 мең пот сабын, 9,6 мең данә урак һ.б. алына.

Я.к.ның эшчәнлеге 11 июнь декретында билгеләнгән вазифалар кысаларыннан чыга һәм авылның хуҗалык тормышы мәсьәләләрен, мәдәни-агарту эшен, Кызыл Армиягә мобилизацияләү һәм ирекләләр туплау һ.б. ны да колачлый; мәс., Лаеш өязендә ярлылардан 900 штыклы махсус батальон төзелә һәм Көнчыгыш фронтка җибәрелә. Казан губернасында Я.к.лары эшләгән чорда барлыгы 6 пехота полкы, бер артиллерия бригадасы һ.б. күп кенә хәрби берәмлекләр оештырыла; Кызыл Армия фондына зур күләмдә икмәк, акча, җылы киемнәр һ.б. туплана. Ком-тлар Кызыл Армия өчен гадәттән тыш революцион салым җыюда да актив катнаша: Казан губернасында 200 млн. сумнан артык акча җыела. Я.к. крәстияннәренең биләмәләрен, ш.и. кулакларның «хезмәт нормасы»ннан калган өлешләрне тартып алып, имана җирләрен бүлә, ш.у. алпавытлар һәм хәлле крәстияннәр милкендә булган эш коралларын һәм җирләрен өләшә. Бигрәк тә хуторлар һәм отрублар тиз арада бетерелә. Тартып алынган җирләр урта хәллеләргә һәм ярлыларга, токымсыз терлек һәм эш кораллары ярлыларга бирелә, токымлы терлек һәм катлаулы техника совхозларга һәм колхозларга тапшырыла.

Кулакларның йогынтысын бетерү авылда икмәккә монополия урнаштыруны җиңеләйтә (к. *Продразвёрстка*). Я.к.лары эшчәнлеге чорында «икмәклеләргә», «икмәккә монополияне бозучыларга» карата продразвёрстка киң репрессия ысуллары кулланып үткәрелә. Кулакларга каршы көрәштә Я.к.лары индивидуаль икътисади салымнар, контрибуцияләр һәм мөлкәтне, йортны, хуҗалык каралтыларын конфискацияләү кебек чаралар куллана. Я.к.лары эшчәнлеге авылда крәстияннәр арасында ризасызлыкның үсүенә, халык кузгалышларына һәм ике хакимлелеккә (хакимиятсезлеккә) китерә. Болар барысы да совет хөкүмәтен Я.к.ларын таратырга мәҗбүр итә. Советларның 6 нчы Гадәттән тыш Бөтенроссия съездының 1918 ел 9 ноябрь карары Я.к.ларына волость һәм авыл советларына сайлаулар үткәрүне йөкли, аннан соң алар таратыла. Казан губернасында советларга сайлаулар һәм Я.к.ларын тарату 1918 нең декабрь ахырында — 1919 ның гыйнварында гамәлгә ашырыла. Ком-тлар эшчәнлеге нәтиҗәсендә губернаның аграр секторына зарар китерелә, Я.к.ларының икътисади һәм сәяси гамәлләреннән кулаклар гына түгел, барлык крәстияннәр дә зур зыян күрә.

*Әд.:* Комбеды РСФСР. М., 1933; Комитеты бедноты: В 2 т. М., 1933; Лебедева А., Шишкин А. Комитеты деревенской бедноты Татарии. К., 1961.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ЯРМА́ ЯРГЫ́Ч**, тары, карабодай, дөге, солы, борчак бөртекләрен ярмага эшкәрткәндә кабыгыннан арындыра торган җайланма. Татар халкы 19 йөз уртасында — 20 йөз башында төрле Я.я.лар кулланган. Бөтен авылга бер (сирәгрәк 2–3) махсус атлы Я.я.лар төзелгән. Я.я.лар механизмны хәрәкәткә китерү ысулы б-н аерылалар. Беришләрендә бер яисә берничә ат авыш түгәрәкне әйләндерә, башкаларында (камилләшкәнрәкләрендә) каешлы яисә шестерняле привод кулланыла. Я.я.лар эшче органының конструкциясе буенча да аерылалар: төйгечләр, тегермән ташлары (яки станоклар). Беренчеләре — иң борынгылар, кул килесен хәтерләтә, икенчеләре — метал станоклы он тарту тегермәннәре — зур ярма «заводларында» кулланыла. Соңрак, тары һәм карабодай бөртеген кабыгыннан арындыру өчен, ике декалы 2ДШС тибындагы стационар декалы станоклар эшләп чыгарыла; тары бөртеге җитештерүчәнлеге — 4,5 *т/с*, карабодайныкы — 3,6 *т/с*. Арпа, борчак һәм башка культураларны кабыгыннан арындыру өчен, 3 ШН тибындагы стационар машиналар эшләп чыгарыла, аларның җитештерүчәнлеге — 1,8 *т/с*. Ярма җитештерү калдыклары терлек азыгы (вакланган ярма, ярма оны), ягулык (тары кабыгы) буларак кулланыла. ТР терр-ясендә бөртекләрне эшкәртә торган ике зур пр-тие бар: «Свияга» (Буа р-нында), 1 нче «Бөгелмә икмәк продуктлары комбинаты» АҖ. Ш.у.к. *Ашлык әзерләү һәм эшкәртү*.

**ЯРМАБА́Ш** (Melica), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 100 гә якын төре билгеле, күбесенчә ике ярымшарның да (Австралиядән кала) уртача поясларында һәм тропик поясның тауларында таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Иенке Я. (M. nutans) барлык районнарда да, биек Я. (M. altissima) һәм Трансильвания Я.ы (M.transsilvanica) Идел алдында очрый. Яфраклы һәм нарат урманнарында, далаланган тау битләрендә үсә. 30–150 *см* биеклектәге үсемлек. Иенке Я. һәм биек Я. шуышма, Трансильвания Я.ы кыска тамырчалы. Сабаклары туры, кытыршы. Яфраклары тар кыяк пластинкалы, йомык җиңсәле һәм кыска кыякчыклы. Чәчәк төркеме — күпепенке яки башаксыман себеркәч. Башакчыклары 2–5 чәчәклеләр, ике җенесле 1–3 чәчәктән һәм чукмарсыман җитлекмәгән чәчәк үсентесеннән тора. Башакчыклар еш кына шәмәхә төстә. Җимеше — бөртекчә. Май-июльдә чәчәк аталар. Җимешләре июль-августта өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Агулы. Трансильвания Я.ы һәм биек Я. — декоратив үсемлекләр; икесе дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЯРМӘКӘ́ЕВ** Искәндәр Энгель улы (1.12.1960, Казан), пед. фән. д-ры (2006), проф. (2007), ТРның атказ. укытучысы (2007). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), Казанның 6 нчы мәктәбендә тарих укыта. 1985–2011 елларда Казан пед. ин-тында, проректор (2008 дән). 2011 дән Казан ун-тында гуманитар-сәнгать белеменең теория һәм технол. каф. мөдире. Хезмәтләре укытучылар әзерләү мәсьәләләренә карый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). РМАнең К.Д.Ушинский исем. медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Воспитание будущего учителя в процессе педагогического образования. М., 2005; Духовно-нравственное воспитание будущего специалиста: становление системы. М., 2008.

**ЯРМӘКӘ́Й РАЙОНЫ́**, БРның көнбатыш өлешендә урнашкан. 1935 елның 31 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 1438 *км*². Үзәге — Ярмәкәй авылы (Уфадан 164 *км* ераклыкта). Халкы — 15737 кеше (2017). Татарлар саны: 1970 тә — 10048, 1979 да — 5582, 1989 да — 9877, 2002 дә — 3699, 2010 да — 6232 кеше. Районда 16 татар, 5 татар-башкорт, 3 татар-рус, 1 татар-чуаш торак пункты исәпләнә. Иң зур татар авыллары: Ярмәкәй (2009 да — 3879 кеше), Иске Турай (699), Әбделкәрим (582), Усман-Ташлы (582). Я.р. терр-ясен үзләштерү чорында татарлар еш кына башкорт авылларына килеп урнаша, һәм соңрак бу авыллар татар авыллары булып китә. Иң беренче булып, татарлар Әбделкәрим һәм Иске Шах (1742 дә), Иске Турай (1743), Ярмәкәй (1747), Усман-Ташлы (1753), Иске Сүлле (1753), Абдулла (1755), Суыккүл (1758) авылларына килеп утыра. Районның 11 авылы: Ярмәкәй, Исламбахты, Кулбай, Түбәнге Карамалы, Рәтамак, Урта Карамалы, Иске Турай, Иске Шах, Суыккүл, Тарказы, Усман-Ташлы мәктәпләрендә татар теле фән буларак өйрәнелә (2016/17 уку елы). Татар иҗат коллективлары: «Ярмәкәй» халык фольклор ансамбле (Ярмәкәй а.), «Ахирәтләр» (Түбәнге Карамалы а.) һәм «Замандашлар» (Усман-Ташлы а.) фольклор ансамбльләре эшли. ТРның Баулы р-ны иҗат коллективлары ел саен Я.р.нда уза торган Ык төбәге халыклары иҗатының төбәкара «Ата-бабалар җире» фестивалендә даими катнаша. Татар һәм рус телләрендә «Ярмәкәй яңалыклары» — «Ермекеевские новости» район г-талары нәшер ителә. Я.р.нда Сов. Союзы Герое Г.Ә.*Мәҗитов* (Яңа Шах а.) һәм мед. фән. д-ры Г.Ф.Бурангулова (Иске Турай а.) туган.

**ЯРМӘКИ́** (чын фамилиясе Насыйров) Зыя (Әхмәтзыя) Шәйхи улы (9.1.1887, Самара губ., Богырыслан өязе Иске Ярмәк а. – 26.11.1965, Үзбәкстан ССРның Фирганә өлкәсе Маргилан ш.), шагыйрь. Чистай (1900–09) һәм Уфа («Галия», 1909–13) мәдрәсәләрендә укый. 1926 елга кадәр туган авылында укыта, аннан соң китапханәдә, балалар йортында (Богырыслан ш.) эшли. Беренче шигырьләре «Шура», «Аң», «Ак юл» ж-лларында, «Бәянелхак», «Казан мөхбире», «Вакыт» г-таларында басылып чыга. 1931 дә Үзбәкстанга күчеп китә, мамык игү совхозларында, 1935–52 дә Фирганә өлкәсенең Ташлак район советында эшли. «Яшьлек дәрте», «Күрсәтәм» (икесе дә — Эстәрлетамак, 1912), «Әдәбият гөлләре» (Оренбург, 1913), «Тойгыларым» (Уфа, 1913) һ.б. шигырь җыентыклары авторы. Үзбәкстан ССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Ак каен. К., 1966.

*Әд.:* Гайнуллин М. Татар әдипләре: Иҗат портретлары. К., 1978; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

*З.З.Рәмиев.*

**ЯРМИ́** (Ярмөхәммәтов) Хәмит Хөснетдин улы (5.5.1904, Төмән губ., Төмән өязе Казар а., хәзер Кырынкүл а. – 30.10.1981, Казан), фольклорчы, филол. фән. д-ры (1972), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1964). Туган авылы мәдрәсәсендә укый. 1923 елдан Төмән шәһәрендә: «Юксыллар чаткысы» г-тасында җаваплы сәркәтип, шәһәр китапханәсендә мөдир, мәктәптә укытучы. 1925–29 да Төмән өлкәсенең Яркәү авылында: ВКП(б)-ның район ком-тында инструктор, халык мәгарифе бүлегендә инструктор. 1930 дан Казанда. Татар пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1934), «Кызыл Татарстан» г-тасында мәдәният бүлеге мөдире, ТАССР Язучылар берлеге идарәсендә җаваплы сәркәтип, Татарстан китап нәшриятында мөхәррир. 1939–71 дә СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында: директор (1942–44), халык иҗаты секторы мөдире (1961 дән). 1940–50 дә Татарстан, Удмурт, Мордва АССР районнарында, Киров, Пенза, Рязань һ.б. өлкәләрдә татар халык фольклорын җыю буенча оештырылган экспедицияләргә җитәкчелек итә. «Халык иҗаты» (1938), «Татар халык иҗаты» (1951), «Татар халык экиятләре» (1–2 т., 1946–56), «Бәетләр» (1960), татар фольклорының күптомлы «*Татар халык иҗаты*» (ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1989) җыентыкларын басмага әзерләүдә катнаша. Хезмәтләре татар фольклоры жанрларына, татар халык авыз иҗаты тарихына, фольклористика тарихына багышлана. Урта мәктәпләр өчен татар фольклоры буенча уку-укыту ярдәмлекләре авторы. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татар халкының поэтик иҗаты. К., 1967.

*Әд.:* Ә х м ә т о в а Ф. Фольклорның киң күгендә Чулпан булып балкырга // Ватаным Татарстан. 1994. 24 июнь; Хәмит Ярми: Галим һәм шәхес. К., 2004; Народно-поэтическое творчество // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967.

**ЯРМИНКӘ́ МӘЧЕТЕ́**, Түбән Новгородта. 1827 елда элекке агач мәчет (1817) урынында җәмәгать акчасына арх. А.Л.Леер проекты буенча ампир стилендә үзәк манаралы, ике катлы мәчет-ротонда рәвешендә төзелә. Ул император Николай I нең 1829 елгы «галиҗәнап фәрманы» нигезендә Россиядә мәчетләр төзелеше өчен үрнәк проект санала. Я.м. Мәкәрҗә ярминкәсе архит-ра ансамбленә керә һәм Бетанкур каналы яры буендагы Мөселман мәйданына урнаша. Үзәк композицияле бина көнбатыш һәм көнчыгыш якларында өчпочмаклы фронтонлы турыпочмаклы ризалитлар чыгып торган түгәрәк кирпеч корылмадан гыйбарәт. Мәчеткә керү ишеге тоскан ордерлы дүрт колонналы портик б-н бизәлгән. Намаз уку залы икенче катта урнашкан, аңа беренче каттагы вестибюльдән ике яклап баскыч күтәрелә. Конуссыман түбә үзәгендә алты кырлы биек шпиль б-н очланган ике яруслы манара. Манараның киселгән дүрт кырлы пирамида рәвешендәге ярусларының икенче әйләнәсендә куб формасындагы тумбалы рәшәткә б-н әйләндереп алынган балкон урнаштырылган. Фасадлар бизәлешендә руслау, ярымтүгәрәк куышлар, пилястрлар, модульоннар һ.б. файдаланылган. 1859 да Я.м.



Түбән Новгород шәһәрендәге Ярминкә мәчете. 1828.

Мәкәрҗә ярминкәсендә чыккан янгыннан зыян күрә, ике ел дәвамында торгызыла. 1930 да рәсми рәвештә ябыла һәм сүтелә.

*Әд.:* Ш у м и л к и н С.М. Нижегородская ярмарка. Н.Новгород, 1996; С е н ю т к и н а О.Н., З а г и д у л л и н И.К. Нижегородская ярмарочная мечеть — центр общения российских и зарубежных мусульман (XIX — начало XX вв.). Н.Новгород, 2005.

*Х.Г. Надыйрова.*

**ЯРМОЛИ́НЕЦ** Семён Евгеньевич (19.4.1934, Одесса ш.), драма актёры, режиссёр, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986). Мәскәүдә Б.Щукин исем. Югары театр уч-щесенең актёрлык (1959) һәм режиссёрлык (1971) бүлекләрен тәмамлый. 1959–67 елларда Одесса рус драма театры актёры, 1967–71, 1978–87 дә Казан Зур драма театры актёры һәм режиссёры (1986 дан баш режиссёр), 1971–77 дә Карпат алды Хәрби округы рус драма театры режиссёры (Украина, Львов ш.). Я. башкарган Виктор («Варшава мелодиясе», Л.Г.Зорин), Илья («Искиткеч бүләк», Е.И.Габрилович, С.Г.Розен), Родионов («Гадәт буенча җыелу», В.С.Розов), де Бризар («Качу», М.А.Булгаков), Гектор («Караклар балы», Ж.Ануй), Батырхан («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин) рольләре логик эзлеклелек, психол. төгәллек б-н аерылып тора. Тышкы сәнгатьчә чаралардан аз гына файдаланып та, актёр һәр героеның кылган гамәлләрен эзлекле яктырта ала. Я. куйган беренче «Гадәти вакыйга» («Обыкновенная история», В.С.Розов; И.А.Гончаров романы буенча; постановка җитәкчесе Н.Ю.Орлов) һәм «Министр хатыны» («Госпожа министерша», Б.Нушич; икесе дә — 1970) спектакльләре үк жанрның төгәл тоемланышы, вакыйгаларның эзлекле үстерелеше, мәгънә тирәнлекләре б-н аерылып тора. Казанга кайткач, нигездә, режиссёр булып эшли. «Без, түбәндә кул куючылар» («Мы, нижеподписавшиеся», А.И.Гельман) һәм «Патша ауда» («Царская охота», Л.Г.Зорин; икесе дә — 1980), «Булмас димә — дөнья бу» («Провинциальные анекдоты», А.В.Вампилов, 1981), «Богауланган мәхәббәт» («Любовь под вязами», Ю.О'Нил) һәм «Ак таулар турында төш» («Сон о белых горах», Ю.П.Астафьевның «Балык патша» («Царь-рыба») әсәре буенча; икесе дә — 1982), «Татуировка ясалган роза чәчәге» («Татуированная роза», Т.Уильямс) һәм «Карагыз, кем килгән!» («Смотрите, кто пришёл!», В.К.Арро; икесе дә — 1983), «Иван һәм Мадонна» (А.И.Кудрявцев) һәм «Зинуля» (А.И.Гельман; икесе дә — 1985), «Һәр заман кешесе» («Человек на все времена», Р.Болт) һәм «Эш» («Дело», А.В.Сухово-Кобылин; икесе дә — 1986) спектакльләрен куя. Я. куйган, эчке бөтенлекләре, актёрлар тарафыннан оста башкарылулары, заманча яңгырашлары һәм мәгънәви тирәнлекләре б-н аерылып торган спектакльләр театр тормышында сизелерлек күренеш була. 1987 дән Мәскәүдә эшли.

Х е з м.: Час между волком и собакой. М., 2012.

*Әд.:* И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ЯРМӨХӘММӘ́ТОВА** Рәйсә Юныс кызы (17.11.1921, Апас р-ны Күккүз а. – 17.4.1980, Казан), сәламәтлек саклау өлкәсе эшлеклесе, ТАССРның атказ. табибе (1963). Дагстан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1947), ТАССР Эчке эшләр министрлыгы системасында эшли. 1955 елдан ТАССР сәламәтлек саклау министрының 1 нче урынбасары, 1959 дан ТАССР сәламәтлек саклау министры. 1964–71 дә ТАССР МС рәисе урынбасары. 1971–79 да ТАССР даруханәләр идарәсе башлыгы. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә. Ике чакырылыш ТАССР ЮС депутаты (1963, 1975).

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**ЯРОСЛА́ВЛЬ ҖАМИ́ГЪ МӘЧЕТЕ́**, Ярославль шәһәрендәге дини архит-ра истәлеге. Ярославльдә мөселман мәхәлләсе 1907 елда оеша. Мәчет имам-хатип М.Йосыпов тарафыннан җыелган акчага 1914 тә төзелә. 1931 дә ябыла; бинада уку йортлары урнаша. 1930 еллар ахырында манарасы сүтелә (1995 тә торгызыла). 1991 дә мәчет бинасының бер өлеше мөселман җәмгыятенә бире-







С.Е.Ярмолинец куйган спектакльләрдән күренешләр: 1. «Ак таулар турында төш», Ю.П.Астафьевның «Балык патша» әсәре буенча; 2. «Зинуля», А.И.Гельман.



З.Я.Яруллин.



М.З.Яруллин.

лә, 1992 дә мәчет тулысынча җәмгыятькә кире кайтарыла. Победа урамында урнашкан. Башта ул ярымтүгәрәк ябык михраблы, төньяк ягында өч катлы манаралы, асы-өсле тәрәзәле турыпочмаклы бинадан гыйбарәт була. Мәчетнең керү ишеге көнчыгыш якта урнашкан. Намаз уку залы төньяк, көнбатыш һәм көнчыгыш яклардан киң балкон б-н әйләндереп алынган. Штукатурланган һәм акка буялган кирпеч диварлы бинага яктылык ике рәтле турыпочмаклы зур тәрәзәләрдән төшә. Сигезкырлы, тар һәм киң кырлар чиратлашып килгән икенче ярус һәм цилиндрсыман тар, балкон б-н әйләндереп алынган өченче ярус манараның үзенчәлеген тәшкил итә. Манараның ярусл композициясе очлаеп килгән биек гөмбәз б-н төгәлләнә. Залның бердәм фәзасы биеклек буенча ике катлыга әверелә, бина 800 кешене сыйдыра.



Ярославль шәһәрендәге җамигъ мәчет.

Элекке дүртпочмаклы тәрәзәләр өске өлеше очлаеп килгән парлы тәрәзәләргә алмаштырылган. Түбә өстенә куб рәвешендәге нигезгә очлы гөмбәз урнаштырылган. Я.җ.м. янәшәсендә тәһарәт-госел бүлмәләре булган, *шәригать* таләпләренә җавап биргән, азык-төлек һәм кием-салым кибете урнашкан корылма төзелгән.

*Әд.:* Черновская В.В. Мусульмане Ярославля. Ярославль, 2000; Нижегородец Махмуд Юсупов — первый имам Ярославской мечети (1878 – 1922) (к 230-летию со дня рождения). Н.Новгород, 2008.

*Х.Г.Надыйрова.*

**Я́РОШ** Станислав Иванович (15.4.1938, Украина ССРның Одесса өлкәсе Цебриково р-ны Великая Зименовка а.), кинооператор, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986). Мәскәүдә Бөтенсоюз кинематография ин-тын тәмамлый (1980). 1961 елдан Казан телевидение студиясендә, 1964 тән студиянең баш операторы, бер үк вакытта, 1973 тән, кино төркеме операторы. Казан телестудиясен оештыруга, иҗади эшләрне формалаштыруга зур өлеш кертә. Үзәк телевидениенең «Вакыт» («Время») программасы өчен сюжетлар төшерә. Я.ның зур эшләре — «Очарга рөхсәт итәм» («Взлёт разрешаю», 1973), «Текә баскычлар» («Крутые ступени», 1978), «Алабуга турында хикәят» («Сказ о Елабуге», 1982), «Әлмәт» («Альметьевск», 1983), «Яруллин мәктәбе» («Школа Яруллина», 1984; Ригада узган 10 нчы Бөтенсоюз спорт фильмнары кино фестивалендә көмеш медаль, 1985), «Вахитов исемендәге» («Имени Вахитова», 1986) фильмнары. Я.ның «Җыр белән күңелемне нурландыр» («Озари мне душу песней», 1986), «Константин Иванов. Тәмамланмаган җыр» («Константин Иванов. Неоконченная песня», 1987) фильмнары Г.Тукай һәм чуаш шагыйре К.Ивановның 100 еллыгына багышлана. 1997 дә Респ-ка «Апуш студиясе» («Студия Апуш») балалар хәйрия фондын оештыра һәм аның президенты була, балалар өчен күп кенә фильмнар, ш. и. «Ләйсән» (1979), «Бездән ничек итеп осталар ясыйлар» («Как нас выводят в мастера», 1985) фильмнарын төшерә. Күпчелек фильмнарының режиссёры да, сценарий авторы да. 2001 дән «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясендә телеоператор-куючы; «С.Сәйдәшев. Музыкаль бүләк» («С.Сайдашев. Музыкальное приношение», 2000), «Бүген бәйрәм! Бәйрәм!» («Сегодня праздник! Праздник!», 2001; «Евразия телефорумы» фестивале дипломы, Мәскәү, 2003), «Көрәш дөньяны яулый» («Куряш покоряет мир», 2004; Тәһранда спортка багышланган фильмнар фестивале дипломы, 2005), «Казанда дүртенче дөньякүләм...» («Четвёртый мировой в Казани», 2005), «Мәхәббәт аллегориясе» («Аллегория любви», 2006) фильмнарын төшерә. 2007 дән Мәскәүдә эшли.

*Е.П.Алексеева.*

**ЯРТИ́ЕВ** Амур Физүс улы (15.5.1965, БАССРның Яңавыл р-ны Яңавыл пос.), икътисадчы, икътисад фән. канд. (2006). ТРның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреаты (2017). 1991 елда Мәскәү И.М.Губкин исем. нефть һәм газ ин-тын тәмамлаганнан соң, Татарстан нефть фәнни-тикшеренү, проектлау ин-тында (Бөгелмә ш.), 2003 тән икътисад бүлегенең сектор мөдире, бер үк вакытта, 2015 тән, Казан ун-тының салым түләү кафедрасында укыта. Хезмәтләре нефть чыгару икътисады өлкәсенә карый. И.М.Губкин исем. бүләк лауреаты (2014). ТР Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касының нефть ятмаларында нефть чыгару темпларын һәм нефть суыртү күләмен арттыру өчен технологияләр комплексын эшләү һәм аларны сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Экономическая оценка проектных решений при разработке нефтяных месторождений для поздней стадии эксплуатации. М., 2006; Инвестиционное проектирование в нефтедобыче: инновации и экономическая оценка. М., 2011; Увеличение продуктивности карбонатных коллекторов нефтяных месторождений. Казань, 2015 (автордаш); Оценка эффективности уплотнения сетки скважин на низкопроницаемых карбонатных коллекторах (на примере месторождений Республики Татарстан). К., 2017 (автордаш).

**ЯРУ́ЛЛИН** Амур Хәйрулла улы (26.1.1939, Украина ССР, Ворошиловград өлкәсенең Антрацит р-ны Үзәк Боково пос.), педиатр, мед. фән. д-ры (1991), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан. мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), Саба р-ны Иске Икшермә участок хастаханәсе баш табибе булып эшли. 1968 елдан ТАССРның Яшел Үзән р-ныдагы «Обсерватория» балалар туберкулёз диспансеры табибе. 1970 тән Казан мед. ин-тының социаль гигиена кафедрасында, 1991–98 дә балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы каф. мөдире, 1998 дән гигиена, хезмәт медицинасы, дипломнан соңгы белем бирү курсы б-н мед. экологиясе каф. профессоры. Хезмәтләре ТРда балалар сәламәтлеген саклауны оештыруга карый.

Хезм.: Оценка физического развития детей Республики Татарстан. К., 1993; Социально-гигиенический мониторинг здоровья детского населения. К., 1997 (автордаш); Репродуктивно-демографические процессы в Республике Татарстан. К., 1998 (автордаш).

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004; Галиуллин А.Н. Профессор Амур Хайруллович Яруллин // Казан. мед. журн. 2009. № 1.

**ЯРУ́ЛЛИН** Гамир Рәшит улы (28.6.1926, Бөгелмә ш.), табиб-паразитолог, мед. фән. д-ры (1966), проф. (1968). Дагстан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук биол. кафедрасында калдырыла, 1960 елдан зоол. каф. мөдире. 1964 тән Волгоград мед. ин-тының биол. каф. мөдире, бер үк вакытта, 1974–77 дә, стомат. ф-ты деканы, 1977–84 тә уку-укыту эшләре буенча проректор. Хезмәтләре эхинококкоз очракларында гомуми һәм аерым паразитология, эпидемиология һәм иммунологиягә карый.

**ЯРУ́ЛЛИН** Заһидулла Ярулла улы (башка мәгълүматлар буенча Баязит улы) (12.10.1888, Мамадыш өязе (хәзер Мамадыш р-ны) Кече Сон а. – 9.10.1964, шунда ук), пианист-ансамблист, муз. әсәрләр авторы. Танылган композиторлар Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннарның әтисе. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Чистайда музыка уен кораллары төзәтү һәм көйләү остасының шәкерте, соңрак музыкант-башкаручы. 1912 елдан Казанда: кинематографларда, ресторааннарда, Шәрекъ клубында уйный; Түбән Новгород ярминкәләрендә, Уфа эстрада сәхнәсендә концертлар б-н чыгыш ясый. Я.ның иҗаты Г.Кариев һәм Г.Тукай тарафыннан уңай бәяләнә, алар аның популяр булып китүенә булышлык итә. «*Сәйяр*» труппасы спектакльләрендә катнаша. «Тукай маршы», җырлар («Җәмилә» һ.б.) авторы. Совет чорында концерт эшчәнлеген дәвам итә, гармуннар ясый. 1923–30 да — Уфада, соңрак — Казанда, 1930 еллар ахырыннан Кече Сон авылында яши.

*Әд.:* Латыйфуллин М. Курайчы малай. К., 1966.

**ЯРУ́ЛЛИН** Мирсәет Заһидулла улы (12.7.1938, Мамадыш р-ны Кече Сон а. – 6.4.2009, Казан), композитор, педагог, ТАССРның, Каракалпак АССР һәм РСФСР-

ның атказ. сәнгать эшлеклесе (1970, 1980, 1985). 1963 елда Казан консерваториясен (А.Леманда композиция классы) тәмамлаганнан соң, шунда ук укыта (1967 дән), татар музыка сәнгате ф-ты деканы (1989 дан). ТАССР Композиторлар берлеге рәисе (1977–89): ул эшләгән елларда Казан үзәгендә Берлеккә махсус бина бирелә; зур масштаблы иҗат кичәләре, ш.и. Идел һәм Урал буе композиторлары музыкасы фестивале уздырыла. Я. иҗатында татар муз. фольклор традицияләре композитор музыкасына хас заманча алым-чаралар б-н бергә үрелеп бара. Я. — татар музыка сәнгатендә беренче «Кеше» ораториясе (1970, Р.Харис шигыре) авторы. Аның җырлары (60 тан артык, ш.и. «Серле чәчәк», «Таң кызы», И.Юзеев шигырьләре; «Син керәсең йөрәгемә», Ә.Ерикәй шигыре) зур популярлык казана.

Әсәрләре: Оркестр б-н скрипка өчен концерт (1962), «Сандугач һәм чишмә» вокаль-симф. поэмасы (М.Җәлилнең шул исем. поэмасы буенча, 1964); Симф. оркестр өчен балалар сюитасы (1969); «Нефтьчеләр» кантатасы (Р.Харис шигыре, 1981); камера-инструменталь әсәрләр; романслар; драматик спектакльләргә музыка; татар халык җырлары эшкәртмәләре һ.б. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1972). Я. тырышлыгы б-н Идел һәм Урал буе композиторлары музыкасы фестивале булдырыла (1982).

*Әд.:* Файзуллаева М.П. Яруллин Мирсаид // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Бахтиярова Ч.Н. Яруллин Мирсаид // Музыкальный энциклопедический словарь. М., 1999; Сайдашева З.Н. Яруллин Мирсаид // Композиторы Татарстана. М., 2009.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ЯРУ́ЛЛИН** Мөнир Гомәр улы (26.10.1954, Арча р-ны Субаш Аты а.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2002), проф. (2003), ТР а.х. атказ. механизаторы (2000). 1977 елда Казан а.х. ин-тын (Казан аграр ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (2008 гә кадәр): 1995–97 дә механизация ф-ты деканы, 1997–2008 дә проректор, механизмнар һәм машиналар теориясе каф.мөдире. Бер үк вакытта, 2006 дан, Казан архит-ра-төзелеш ун-тының юл төзү машиналары каф. профессоры. Хезмәтләре махсус структуралы фәзаи механизмнарны өйрәнүгә һәм машиналар төзү сәнәгатендә файдалануга багышлана. Я. эшләнмәләрне өч үлчәнешле чистартуның һәм сыекчлыклы эшкәртүнең теоретик нигезләрен эшли. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2005).

Хезм.: Трёхмерная гидродинамическая очистка изделий. К., 2001; Курсовое проектирование по теории механизмов и машин. К., 2008 (автордаш).

**ЯРУ́ЛЛИН** Рафинат Самат улы (5.3.1943, Удмуртия АССРның Можга ш.), химик-технолог, химия фән. д-ры (2009), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2013), ТРның атказ. химигы (1993). Казан химия-технол. ин-тын һәм Мәскәү идарәчелек ин-тын тәмамлый (1970, 1980). 1970–94 елларда «Түбәнкаманефтехим» АҖдә (цех башлыгы, 1979 дан газ з-ды баш инженеры, 1987 дән җитештерү бүлеге башлыгы). 1994 тән «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖдә (ген. директор), бер үк вакытта, 2006 дан, Казан технол. ун-тының ясалма каучук каф. профессоры. Хезмәтләре нефть химиясе өлкәсенә карый. Я. югары сыйфатлы нефть химиясе һәм химик продукция җитештерүнең экологик яктан куркынычсыз, ресурсларны саклаучан технологияләрен эшләү һәм сәнәгатьтә үзләштерү процессында актив катнаша (РФ Хөкүмәте бүләге, 2008). ТР Дәүләт бүләге «1999–2003 елларда һәм 2004–2008 елларда Татарстан Республикасы нефтегазохимия комплексын үстерү программаларын фәнни формалаштыру, эшләү һәм гамәлгә ашыру» (2009) эшендә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 6 патенты бар. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Россия может и должна стать мировым лидером в области газохимии // Газохимия. 2011. № 2; Флагманы на мели // Химия и бизнес. 2011. № 1.

**ЯРУ́ЛЛИН** Рәшит Низам улы (28.6.1954, Чистай р-ны Зирекле а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2002), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2009). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1997), Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли: бүлек башлыгы (1990 елдан), баш технолог (2000 нән), директор урынбасары — баш инженер (2005 тән). Хезмәтләре химик технол. процесслары һәм аппаратларына карый. Я. җитәкчелегендә җепселле материалларны дозалау, гетероген мохитләрдә масса алмашу процессларын тизләтү өчен гидроакустик тәэсир итү аппаратлары, агрессив сыекчаларны нечкәләп чистарту фильтрлары, пычрак суларны чистарту өчен гидроциклоннар эшләнә. Ул нитрат к-талы целлюлоза эфирларын булдыруның өзлексез технологиясен һәм сыгылмалы технологиясен (модуль тибындагы), карбоксиметилцеллюлозаның натрий тозларын җитештерү технологиясен, углерод б-н баеткычның рецептурасын һәм аны корычны легирлау өчен җитештерү ысулын тәкъдим итә (ТР Дәүләт бүләге, 2009). Фәнни тикшеренүе нәтиҗәләре Оборона министрлыгы, лак-буяу, нефть сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 70 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХның көмеш медале б-н бүләкләнә. Сугыш кирәк-яраклары һәм махсус химия тармагының мактаулы хезмәткәре (2004).

*Әд.:* Аюпов М.Ю., Юсупов И.В. Изобретательство в Республике Татарстан. К., 2001; Лучшие люди России: Энцикл. М., 2004. Ч. 2.

**ЯРУ́ЛЛИН** Солтан Сөнгатулла улы (25.7.1914, Казан губ., Лаеш өязе Татар Агайбашы а. — 13.3.1998, Тәтеш ш.), спортчы, тренер (стендта ату), СССРның спорт остасы (1964), СССРның атказ. тренеры (1988). 1нче Ленинград арт. уч-щесен тәмамлый (1937). 1933–56 елларда СССРның Кораллы көчләре сафларында хезмәт итә, Бөек Ватан сугышында катнаша, подполковник. 1956–60 та Калининград өлкәсенең Черняховск шәһәрендә яши. 1960 тан Тәтештә; стендта ату буенча балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбен ачуны башлап җибәрүче һәм мәктәпнең директоры (1961–86). Шәкертләре арасында — РСФСР, СССР, Европа, дөнья, Олимпия уеннары чемпионнары, рекордчылары, медаль алучылар С.А.*Дёмина*, Л.Г.*Володина*, Р.В.Демидов, Ю.В.*Шегуров* (СССРның халыкара класслы спорт остасы), А.Г.Бычков, Ю.А.Моргачёв, С.Ю.*Протасов*, Н.В.Спиридонов, Ю.А.Столыпин, Н.М.Тенилин, Т.И.Шлячкова һ.б. Ленин ордены, Кызыл Байрак, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. 2004 тә Тәтештә Я.га бюст куела, бер урамга аның исеме бирелә.

*Әд.:* Марихин Б.Ф. Тетюшские стрелки. К., 1985.



Ф.Г.Яруллин.

**ЯРУ́ЛЛИН** Фәнис Гатаулла улы (9.2.1938, Баулы р-ны Кызылъяр а. – 9.12.2011, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1985), ТРның халык шагыйре (2001). Казан ун-тын тәмамлый (1970). 1958 елдан урын өстендә. Авыруына карамастан, характер ныклыгы, тормыш иреге темасы язучының күпкырлы иҗатына үтеп керә. Лирик, лирик-публицистик, юмористик шигырьләр авторы: «Мин тормышка гашыйк» (1964), «Алмалар пешкән чакта» (1971), «Аерылмас дустым» (1975), «Сулыш» (1978), «Танышлар арасында» (1980). «Нәсел агачы» (1989), «Коткарыгыз» (1990), «Җан авазы» (1994), «Йөрәк тавышы» (2005), «Нурсөя» (2006) поэмаларына тормышчан пафос, чынбарлыкны фәлсәфи аңлау, нечкә психологизм, интонациянең музыкальлеге хас. Я.ның проза әсәрләре тематикасы да күптөрле: иҗтимагый тормышның җитешсез якларын тәнкыйтьләү — «Һәркемнең үз сукмагы» (1982), «Туган көн бүләге» (1984), «Урман кызы» (1998) хикәяләр җыентыклары, «Кайту» (1992), «Мәхәббәт упкыны» (2001) повестьлары; хәзерге заман хатын-кызы — «Кыйгак, кыйгак каз кычкыра» (1994), «Бүләк» (1999), «Портрет» (2000) повестьлары; балалар йортларында тәрбияләнүче балаларның язмышлары — «Яралы язмышлар» (2000) повесте. Я.ның автобиографик «Җилкәннәр җилдә сынала» повесте авторга аеруча киң танылу китерә, әсәрдә язмыш һәм үзенең көчсезлеге б-н көрәшеп, тормышта үз урынын тапкан кешенең катлаулы юлы күрсәтелә. Я.ның пьесалары Татарстан, Башкортстан, Мари Респ-касы театрлары сәхнәләрендә куела. «Әнә килә автомобиль» (Татар акад. театры сәхнәсендә куела, 1974), «Сөембикә егет сайлый» (Татар драма һәм комедия театры сәхнәсендә куела, 1992) спектакльләре аеруча зур уңыш казана. Балалар өчен «Минем елмаю» (1968), «Гел ашыгам» (1970), «Язмышлар язылганда»



Ф.З.Яруллин.

(1979), «Зәңгәр күлдә ай коена» (1990), «Биюче бака» (1996), «Серле дөнья» (1997) һ.б. китаплар авторы. Публицистик әсәрләрендә татар теле һәм әдәбияты, татар халкының хәзергесе һәм киләчәге мәсьәләләре чагылыш таба («Көн сулышы» җыентыгы, 1997 һ.б.). Я. шигырьләренә комп. Ф.Әхмәтов («Ташлама мине...»), Р.Гатауллин («Әйттең миңа, матурым»), Ә.Хәйретдинов («Иң гүзәл кеше икәнсез») иҗат иткән җырлар популярлык казана. Я.ның әсәрләре рус, инглиз, казакъ, һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1978), ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1978) лауреаты. Халыклар дуслыгы, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Җилкәннәр җилдә сынала: повестьлар. К., 1986; Сайланма әсәрләр: 5 томда. К., 2004; Әсәрләр: 3 томда. К., 2007–08.

*Әд.:* Фәнис Яруллин: тормыш юлы һәм иҗаты. К., 2006; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2. *С.Г.Хәкимова.*

**ЯРУ́ЛЛИН** Фәрит Заһидулла улы (1.1.1914, Мамадыш өязе Кече Сон а., башка мәгълүматлар буенча Казан — 17.10.1943, Беларусь Респ-касы Витебск өлкәсенең Дубровно р-ны Түбән Тухиня авылындагы «Рыленки» мемориаль комплексында җирләнә), композитор. 1934–38 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә (Г.Литинский классы) укый. Камера-инструменталь, камера-вокаль әсәрләр, татар халык җырлары эшкәртмәләре авторы. Татар музыка сәнгате тарихына Я. милли балетка нигез салучы буларак килеп керә. Ул иҗат иткән беренче татар *«Шүрәле»* балеты (Г.Тукай әкияте буенча; Ә.Фәйзи, Л.Якобсон либр.) 1945 тә Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә куела. Балет илебездә һәм чит илләрдә киң танылу ала, татар муз. культурасының алтын фондын тәшкил итә. Я. иҗаты татар милли балеты үсешенә билгеле бер юнәлеш ясый. Аның музыкасы мелодика һәм гармония өлкәсендә яңалыгы, муз. фикерләү масштабы, татар халык музыкасы традицияләренең гомумиләштерелүе, интонацион байлыгы һәм сәнгатьчәлеге б-н аерылып тора.

Әсәрләре: Симфония (1 нче кисәк), Кыллы квартет, Виолончель һәм фортепиано өчен соната, Фортепиано өчен сонатина һәм этюд; скрипка һәм фортепиано өчен пьесалар: «Иртәнге җыр», «Хыяллар», «Бию көе»; романслар: «Цыгане», «Не пой, красавица, при мне» (А.Пушкин шигырьләре); 20 дән артык җыр: «Егерменче елларда», «Очкычлар», «Комсомолка-партизанка» (Ә.Ерикәй шигырьләре). ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1958, үлгәннән соң). Бөек Ватан сугышында катнаша. Белоруссияне азат итү өчен барган сугышта үлә. Казан муз. уч-щесе бинасына мемориаль такта куела; Казанда бер урам аның исемен йөртә.

*Әд.:* Б а х т и я р о в а Ч.Н. Фарид Яруллин. К., 1960; А л м а з о в а А.А. Фарид Яруллин и татарский балет. К., 1987; Композиторы Татарстана. М., 2009.

**ЯРУ́ЛЛИН ФӘРИ́Т МУЗЕЕ́**, Мамадыш р-ның Кече Сон авылында. 1997 елда ТР Дәүләт музее (2001 дән — Милли музей) ф-лы буларак ачыла, 2007 дән муниципаль музей. Мәктәп бинасында урнашкан. Экспозиция мәйданы — 100 $м^2$, фондларында 1200 дән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Композиторлар Заһидулла Ярулла улы һәм Фәрит Заһидулла улы Яруллиннар тормышы һәм иҗатына багышланган беренче залда фоторәсемнәр, З.Яруллинның «Тукай маршы»; Ф.Яруллинның «Партизанка», «Сәҗидә»,



Фәрит Яруллин музее. Экспозиция фрагменты.

«Соңгы көрәшкә» әсәрләре кульязмаларының күчермәләре, Ф.Яруллинның хатыны — балерина Галина Сачекка язган хатлары күчермәләре урнаштырылган. «Мирсәед Яруллин. Тормышы һәм иҗаты» залында экспозициягә фоторәсемнәр, шәхси китапханәсеннән китаплар, композиторның музыка уен кораллары куелган. «Татарстан композиторлары» залындагы экспозиция татар проф. музыкасы үсешенә зур өлеш керткән күренекле сәнгать эшлеклеләре С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов, Р.Яхин, Җ.Фәйзи һ.б. турындагы материаллар б-н таныштыра. Этнография бүлегендә хезмәт кораллары, көнкүреш әйберләре, төбәкнең 19 йөз ахыры – 20 йөз башындагы гамәли-бизәлеш сәнгате предметлары урын алган. Музей ел саен халыкара театр (27 март), музейлар (18 май), музыка (1 октябрь) көннәрен билгеләп уза. «Яраткан көйләр», «Ил сакчылары сезнең өчен!» һ.б. тематик кичәләр үткәрелә. Музей директорлары: Ф.Г.Мөхәммәтҗанов (1997–2000), Г.К.Рәхимова (2001–12), В.Х.Хәбибуллина (2012 дән).

**ЯРУ́ЛЛИНА** Алсу Гыйният кызы (13.8.1949, Чүриле р-ны (хәзер Арча р-ны) Яңа Чүриле а.), тел галиме, филол. фән. канд. (2005). ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2008). Казан ун-тының филол. ф-тын (1971), Мәгълүмат органнары хезмәткәрләренең белемен күтәрү ин-тын (1980, Мәскәү) тәмамлый. Арча урта мәктәбендә рус теле укыта. 1972–74 елларда ВЛКСМның Арча район ком-ты 2 нче секретаре булып эшли. 1974 тән Казанда хисаплау техникасын халык хуҗалыгында куллану фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында (ГНИПИ-ВТ, 1986 дан «Волга» ФПБ, 1993 тән ТР МК каршындагы Социаль тикшеренүләр үзәге) фәнни мәгълүмат бүлеге кураторы. 1991 дән Тел, әдәбият һәм тарих ин-тының Татар энциклопедиясе бүлеге (1992 дән ТР ФА бүлеге, 1994 тән Татар энциклопедиясе ин-ты, 2014 тән Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-ты) фәнни хезмәткәре, 1993 тән фәнни методика һәм контроль бүлеге мөдире урынбасары, 1998–2016 да энциклопедик басмаларны татар телендә әзерләү бүлеге мөдире, 2017 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Я. татар энциклопедиясен әзерләүнең методик нигезләрен һәм техник-орфографик таләпләрен билгели, татар телендә фәнни терминологияне барлауга һәм камилләштерүгә зур өлеш кертә. 2005–10 елларда ТР МК каршындагы терминология комиссиясе әгъзасы. Ике дәүләт телендә ТРның муниципаль берәмлекләре исемлеген төзүдә һәм татар телендә ТРның адм. һәм физик картасын эшләүдә катнаша. Рус һәм татар телләрендә «Татарский энциклопедический словарь» (1999) һәм «Татар энциклопедиясе сүзлеге»н (2003), ш.у. күптомлы «Татар энциклопедиясе»н (1–6 т., 2008–18) булдыруга зур көч куя.

Хезмәтләре рус һәм татар телләрендә Татар энциклопедиясен эшләү һәм татар телендә фәнни терминология мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татарлар һәм Татарстан: «Татар энциклопедиясе»нең 5 нче томы дөнья күрде // Фәнни Татарстан. 2017. № 2; Истоки татарской энциклопедической мысли // Из истории Татарстана и татарского народа: Сб. статей молодых учёных и аспирантов Ин-та татарской энциклопедии АН РТ. К., 2003. Вып. 1; Понятие как компонент структуры энциклопедических изданий // Проблемы вербализации концептов в системе языка и текста: Материалы междунар. симп. (Волгоград, 22–24 мая 2003 г.). Волгоград, 2003. Ч. 2; Взаимодействие русского и татарского языков в топонимии Татарстана (по материалам «Татарской энциклопедии») // Российская многонациональная энциклопедистика: история и современность: Сб. статей Всерос. науч.-практ. конф. с междунар. участием Ин-та татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ (Казань, 2017 г.). К., 2017 (автордаш); Англицизмы и их освоение в татарской языковой культуре (по материалам «Татарской энциклопедии») // Вестн. КазГУКИ. 2018. № 3 (автордаш).

*Әд.:* Яруллина Алсу Гиниятовна // Казанская лингвистическая школа. Кн. 1. Казанская тюркская лингвистическая школа. К., 2008.

**ЯРУ́ЛЛИНА** Гүзәл Рифат кызы (26.6.1965, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2012). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң (1986), Ленинград гражданнар авиациясе идарәсе Мурманск берләштерелгән авиаотрядының Поной аэропортында эшли. 1992 елдан Үзбәкстан Респ-касы Ташкент өлкәсе Красногорск посёлогының 24 нче медсанчастенда хисапчы. 1994 тән Казан финанс-икътисад ин-тында. Хезмәтләре сәнәгать пр-тиеләренең тотрыклы үсеше б-н идарә итү мәсьәләләренә карый. Сәнәгать пр-тиесенең структуралы-ди

намик бәяләүгә нигезләнгән үсеш мониторингы моделен эшли.

Хезм.: Методология обеспечения устойчивого развития промышленного предприятия. К., 2010; Теоретические основы обеспечения устойчивого развития в процессе управления промышленным предприятием // Аудит и финансовый анализ. 2010. № 6. *Ф.С.Зыятдинов.*

**ЯРУ́Т** (Thlaspi), кәбестәчәләр семьялыгыннан бер- яисә күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы, чүп үлән. 60 тан артык төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында киң таралган. ТРда бер төре — кыр Я.ы (T. Arvense) үсә; Биеклеге 15–45 *см* лы туры сабаклы берьеллык үсемлек. Үзәк тамыр системалы. Сабак яфраклары утырма, озынча, сабак төбендә уксыман-тешле, тамыр янындагылары — озынча. Чәчәкләре вак, ак, 4 таҗлы, чәчәк чугына җыелган. Апрель ахырыннан август беткәнчегә кадәр чәчәк ата. Җимеше — кузак, түгәрәк, эре, яссыланган, канатлы киль һәм күпсанлы майлы вак орлыклы. Бөртеклеләр һәм яшелчә культуралары чәчүлекләрен, бакчаларны чүпли. Орлыктан үрчи (бер үсемлек 10 меңгә кадәр орлык бирә), туфракта тишелүчәнлеген 7 елга кадәр саклый, бер җәй эчендә 2–3 буын бирә ала. Көрәш чаралары: алдан йомшартып туңга сөрү, язын чәчүлекләрне тырмалау, сызма культураларның рәт араларын үз вакытында эшкәртү, гербицидлар куллану. Я.ны сыерлар ашаган очракта сөттә тәмсез ис (сарымсак исе) барлыкка килә. Дару, яшелчә, май бирә торган үсемлек. Яфракларын запаска әзерлиләр, язын һәм җәй башында җыялар һәм киптерәләр; алардан салатлар һәм щи әзерлиләр. Орлыкларыннан техник максатларда май алалар.

*Әд.:* Атлас сосудистых растений Татарстана. К., 2008.

**Я́РЦЕВ** Игорь Васильевич (3.7.1934, хәзер Волгоград өлкәсенең Урюпинский р-ны Бесплемяновский пос. — 31.1.2006, Казан), аралашу юллары инженеры, Татарстан «Татавтодор» автомобиль юллары ремонт-төзелеш берләшмәсе башлыгы (1983–97), РСФСРның мактаулы юлчысы (1984), ТАССРның, РФнең атказ. төзүчесе (1989, 1992), Россиянең мактаулы транспорт хезмәткәре (1994). Сталинград шәһәр хуҗалыгы инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), Татарстан автомобиль юллары ремонт-төзелеш берләшмәсендә эшли (1973 елдан). 1964–73 тә Иркутск өлкә юл төзелеше трестының баш инженеры. Я. җитәкчелегендә Казан–Чаллы автомобиль юлы һәм Алабуга–Ижевск, Казан–Пермь, Казан–Оренбург, Казан–Ульяновск, Казан–Мәскәү юлларының респ-ка участоклары (барлыгы 6 мең *км*), Казан янында Идел елгасы аша күперле кичү, Зөя, Ык, Иж, Мишә, Чирмешән елгалары аша күперләр һ.б. (барлыгы 35 мең *м*) проектлана һәм төзелә, аларны ел әйләнәсе файдалану җайга салына. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты. Медальләр, ТАССР ЮС Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. «Тататвтодор» АҖ бинасына Я. хөрмәтенә мемориаль такта куела.

*Әд.:* 100 выдающихся дорожников России. М. 2007. *Г.Я.Мәүлетова.*

**ЯРЦО́В** Януарий Осипович (15.4.1792, Екатеринбург ш. — 3.12.1861, С.-Петербург), шәркыятьче галим, тәрҗемәче, шәрекъ телләре һәм әдәбияты магистры (1816). Казан ун-тын тәмамлый (1812). И.И.Хәлфин һәм Х.Д.Френ шәкерте. Шәрекъ телләре, ш.и. татар теле белгече. Татарча сөйләм телен өйрәнү максатыннан күпмедер вакыт Казанның Татар бистәсендә, 1816 елда Казан губернасының Мамадыш өязе Саба авылында яши. 1817 дә Иранда А.П.Ермолов илчелегенә беркетелә. 1819–61 дә Россия Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаментында тәрҗемәче. Сәяхәте нәтиҗәләреннән чыгып, ун-т Советына «Иранга кыскача сәяхәт журналы» («Краткий журнал путешествия в Персию»), «Тифлистән Әстерханга күчкән вакытта алып барылган көндәлек язмалар» («Дневные записки, веденные во время переезда от Тифлиса до Астрахани») һәм «Фарсы халкының дине хакында фикер йөртү» («Рассуждение о религии персиян») хезмәтләрен тәкъдим итә. Хезмәтләре археографиягә, рус телендәге шәрекъ алынмаларын өйрәнүгә карый. Хива дәүләте ханы тарихчы Әбелгазыйның «Төркиләр шәҗәрәсе» («Родословная тюрок») хезмәтен рус теленә тәрҗемә итә (басылмаган). Одессадагы Тарихны һәм борынгы ядкәрләрне өйрәнү җәмгыяте әгъзасы (1843 тән). Персиянең 2 нче дәрәҗә Арыслан һәм Кояш ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Ярлыки Тохтамыша и Сеадет-Герея // Зап. Одес. об-ва истории и древностей. 1844. № 1 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1; Из истории Казанской иранистики: Сб. док. К., 2013. *Р.М.Вәлиев.*

**ЯРЫМКАТЫКАНАТЛЫЛА́Р**, к. *Кандалалар*.

**ЯРЫМТЫ́К**, татар мифологиясе персонажы, Себер халыкларында, фарсыларда, гарәпләрдә таралган ярымкеше-ярымрух вариантларының берсе. Урал татарлары фольклорында *Шүрәлегә* якын. А.Х.Садыйкова тарафыннан 1977 елда Свердловск һәм Пермь өлкәләрендә язып алынган шул ук исемдәге легендада Я.ның барлыкка килүе кешегә җибәрелгән бозым б-н аңлатыла. Я. урманда яисә мәгарәләрдә яши. Кошка әверелеп, оядa яши ала. Очраган кешене кытыклап үтерергә мөмкин.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты: Дәреслек. К., 2005. *Ф.И.Урманчеев.*

**«ЯРЫ́Ш»**, Әлмәт р-нындагы а.х. пр-тиесе. 1930 елда «Ирек» к-зы буларак оештырыла, 1959 дан «Я.». 1998 дә авыл кооператив хуҗалыгы, 2005 тән ҖЧҖ итеп үзгәртелә. Үз эченә Габдрахман (үзәк утар) һәм Тайсуган авылларын ала. А.х. җитештерүендә 71 кеше эшли (2017); а.х. файдалану җирләренең мәйданы 5097,2 *га*. Төп тармаклары — бөртекле ашлык, сөт, ит җитештерү. 2017 дә 3627 *т* бөртекле ашлык, 907 *т* сөт, 80 *т* ит җитештерелә. Бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 24 *ц* тәшкил итә, һәр сыердан уртача савым — 2357 *кг*. 100 *га* а.х. файдалану җирләренә күчереп исәпләгәндә 178 *ц* сөт, 15,7 *ц* ит җитештерелә. Хуҗалык соц.-икътисади үсештәге уңышлары өчен берничә тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКларының мактау грамоталары, дипломнары һәм күчмә Кызыл байрагы б-н, 32 хезмәткәр орден һәм медальләр б-н бүләкләнә. Җитәкчеләре арасында — С.С.*Әхтәмов* (1970–2003), Р.М.Шәяхмәтов (2003 тән). *И.Н.Афанасьев.*

**ЯСА́** (монг. — закон, устав), 1206 елда *Чыңгызханны* бөек хан итеп сайлау корылтаенда аның тарафыннан халыкка игълан ителгән законнар җыелмасы. Җүвәйни сүзләренә караганда, «хакимлегенең башлангыч чорында, аңа башка монгол кабиләләре кушылганда, начар гадәтләрне бетерде... һәм акыл кушуы буенча, яхшы, лаеклы гадәтләр урнаштырды». Я.ның төп таләпләре «саф, бозылмаган, гадел, галим һәм акыллы» кешеләрне олылау һәм хөрмәт итү, яманнарны һәм гаделсезләрне җавапка тарту; барлык диннәрне ихтирам итү; зина кылуны, караклыкны, ялган шаһитлек бирүне, хыянәтне һ.б.ны тыю. Тәхеткә варислык, башка илләр һәм халыклар б-н мөнәсәбәт тәртипләре күрсәтелә. Я.да хәрби хезмәт (мәс., барлык ирләр дә 10, 100, 1000 һәм 10000 кешелек отрядлардан торган гаскәрдә хезмәт итәргә тиеш), җинаять җаваплылыгы (күп җинаятьләргә үлем җәзасы карала), кайбер гаилә һәм мирас хокуклары һ.б. турында әйтелә. Тулы тексты сакланмаган; аерым өлешләре Рәшидетдин, Җүвәйни, Мәкризи һ.б. авторлар тарафыннан китерелә.

*Әд.:* Попов П. Яса Чингисхана // Зап. Вост. отд-ния Рус. археол. об-ва. 1907. Т. 17; Вернадский Г.В. История России: Монголы и Русь. М., 2000. Т. 3.

**ЯСА́К**, 13–18 йөзләрдә феодаль бәйлелектәге кешеләр — *ясаклылар* — түләргә тиешле натураль салым. «Ясак» сүзе монгол телендәге «Яса»га барып тоташа һәм ул «устав», «закон» дигәнне аңлата. Алтын Урдада һәм, ул таркалганнан соң, татар ханлыкларында «Я.» термины б-н закон тәртибендә гамәлгә кергән салымнар һәм җыемнар җыелмасы белдерелә. 16–18 йөзләрдә Рус дәүләтендә Я. дип Идел буе һәм Себердә яшәүче рус булмаган халыклар түләргә тиешле натураль салым атала. Мәҗбүри салым буларак, подданныйлыкның бер билгесен белдерә. Я.ның күләме һәм формасы махсус «ясак кенәгәләрендә» күрсәтелә; ул затлы мех, бал, икмәк, терлек һ.б. б-н түләнә. Я. окладлы (һәр ясак түләүчедән билгеле бер оклад — берәмлек буенча) һәм окладсыз (күләме күрсәтелми) була. Окладлы Я. — Идел буенда, ә окладсызы Себердә һәм Ерак Көнчыгышта таралыш ала. Идел буенда Я. җыю б-н *Казан сарай идарәханәсе* шөгыльләнә. Башта ул һәр аерым кабиләдән, ырудан, авыл җәмгатеннән, соңрак адм.-терр. берәмлектән (йөзләр, өязләр, волостьлар, станнар һ.б.) җыела. Казан татарларында һәм башкортларда Я. җир буенча, ә Себер татарларында терлек хисабы буенча алына. 1710 да Казан губернасы Казан өязе ясаклы кешеләре 16472 Я. түләүдә катнаша. 18 йөздән Я. җан башыннан салым — акчалата җыем б-н алыштырыла (Идел буенда 1720 еллардан).

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ЯСАКЛЫ́ БАРЫ́Ш** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Коры Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 231 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигезләнә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек, он тарту, тимерчелек һәм йон-тукыма ману б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, чиркәү-приход мәктәбе (1900 да ачыла), 3 су һәм 5 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 тимерче алачыгы, йон-тукыма ману йорты, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1787 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Барыш волостенда. 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 152 ир-ат; 1859 да — 758, 1897 дә — 1539, 1908 дә — 1766, 1920 дә — 1752, 1926 да — 1285, 1938 дә — 812, 1949 да — 618, 1958 дә — 523, 1970 тә — 426, 1979 да — 599, 1989 да — 311, 2002 дә — 249 кеше.

**ЯСАКЛЫЛА́Р**, Идел буенда, Урал янында һәм Себердә яшәгән, феодаль бәйлелектә гомуми характердагы салым — *ясак* түләгән рус булмаган халыклар. Я. казна җирләрендә яшәгәннәр, дәүләт файдасына йөкләмәләр үтәгәннәр, шәхси ирекле саналганнар. Я. категориясенең барлыкка килүе *Хәзәр каганлыгы* һәм *Идел буе Болгар дәүләте* чорына барып тоташа, ул заманда аларны — «салымлы кешеләр», *Алтын Урдада* һәм татар ханлыкларында ясак түләүчеләрне «кара халык» дип атаганнар. Я. җәмгатьләр — берничә торулыкны берләштергән җыеннар булып яшәгәннәр. Җәмгать үзәгенең исеме б-н аталган. (мәс., «Ашыт җыены»). Җәмгатьләр башында аксакаллар, абызлар торган; алардан югары баскычны җыен төркемнәре кергән округлар, вилаятьләр яки даругалар б-н идарә иткән хан чиновниклары һәм җирле феодаллар биләгән. Гомуми җыелыш та җыен дип исемләнгән; ул барлык җәмгатькә кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткән, а.х. эшләренең башлану һәм төгәлләнү вакытын, чәчүлекләрне урлаулардан һәм янгыннардан саклау тәртибен билгеләгән, җыенга тәгаенләнгән ясакны һәм йөкләмәләрне бүлгән. Җыен карары мәҗбүри булган һәм крәстияннәр өчен гадәти хокук чыганагы сыйфатында кабул ителгән. Җәмгатьләр нигезендә алга таба ясак йөзлекләре — халыктан салымнар җыю өчен бердәм терр. берәмлекләр оештырылган. Казан яуланганнан соң (1552), аңарчы җирле халык Казан ханнарына түләп килгән ясакларны «үзләренә күчергәннәр». Соңрак әлеге сәясәт Себер халыкларына да җәелдерелә. Авыру һәм гарип кешеләрдән кала, 18 яшьтән 50 яшькәчә (соңрак 16 дан 60 яшькәчә) барлык ирләр Я. булып саналган. 16 — 18 йөзләрдә «Я.» атамасы б-н бергә «ясаклы чуашлар» һәм «ясаклы татарлар» атамалары да кулланылган. Я. махсус ясак китапларына теркәлгән. Аларның саны әледән-әле кабатланган исәп алулар б-н тикшерелгән; мәгълүматлар ясак комиссияләре тарафыннан төзәтелгән. Я.ның подданныйлыкның тышкы чагылышы — ясак түләргә мәҗбүр итү чарасы шертьтән (ант) гыйбарәт булган. Идел буенда яшәгән Я.ның хуҗалык эшчәнлеге нигезен игенчелек, терлекчелек, затлы мехлы җәнлекләр аулау тәшкил иткән. Урманлы һәм урман-дала районнарында чолыкчылык, балыкчылык, сунарчылык һ.б. кәсепләр сизелерлек роль уйнаган. Барлык Я. да дәүләт җирләреннән файдаланганнар. Төбәкнең кара туфраклы районнарында ясаклы имана җире 5–10 дис. булган. Я.ның өчтән бере чамасы 5 дис.дән кимрәк җир биләгән. 17 йөздә, төбәкнең колониялəштерелүе б-н бәйле хәлдә, Я.ның җирләре актив рәвештә алпавытлар, йомышлылар, ш.у. чиркәү тарафыннан үзләштерелә башлаган; мәс., 17 йөзнең уртасында Казан өязендә рус йомышлыларының җирләре 2 тапкыр арткан, зур монастырь хуҗалыкларына ия 20 монастырь нигезләнгән. Әммә хөкүмәт Я.ның санын киметмәскә омтылган, чөнки ясак дәүләт керемнәренең мөһим өлешен тәшкил иткән. 1682 елгы фәрман буенча рус алпавытларына татар, чуаш, мари һәм мордва Я.ының җирләрен тартып алу һәм үзләренеке дип игълан итү тыелган. 1685 тә тыю кабатлана һәм хөтта көчәйтелә: үзләштерелгән җирләрне кире тартып алырга һәм «элеккечә үк ясакка» кайтарырга әмер бирелә. Моннан тыш 17 йөзнең 2 нче яртысында йомышлыларның кайбер бөлгән вәкилләре Я. катлавына күчерелә. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында Я.ның хәле тагын да кыенлаша. Ясаклы имана җиренең мәйданы элеккечә үк калса да яки кечерәйсә дә, ясакның күләме арта бара. Я. ш.у. дәүләт файдасына шәһәр, ям хезмәтләрен башкаралар һ.б. йөкләмәләрне үтиләр; гомумдәүләт ихтыяҗлары өчен төрле мәҗбүри эшләргә (шәһәрләр, саклану корылмалары төзелеше, корабльләр төзүгә урман әзерләү һ.б.) җәлеп ителәләр. Ясак җыю вакытында җирле хакимият еш кына башбаштаклыклар кылган, бу Я.ның ризасызлыгына китергән. Алар шикаятьләр язганнар, Урал алды һәм Себернең аз халыклы җирләренә качып киткәннәр. Бу процесс аеруча 1680 елларда киң колач алган. 1688 дә Казан сарае идарәханәсе карамагындагы җирләрдә качкын крәстияннәрне эзләү турында приказ чыгарылган. Рус булмаган халыклар (татарлар, марилар, удмуртлар, башкортлар һ.б.) өчен дәүләт йөкләмәләренең авырлыгы ирексезләп христианлаштыру һәм алга таба руслаштыру б-н ксенләшкән; нәтиҗәдә, Я.арасында аерым бер катлау — яңа чукынган Я. барлыкка килгән. Киң колачлы колонияләштерү, социаль, дини һәм милли изүнең көчәюе Казан төбәгендәге күтәрелешләргә, *Җангали хәрәкәтенә (1615–16)*, *Крәстияннәр кузгалышына (1670–71)* сәбәп була. 1724 тән Я. юридик яктан *дәүләт крәстияннәренә* тиңләштерелә, ясак урынына алар өчен җан башыннан салым кертелә.

*Әд.:* Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603. К., 1990; Н а с ы р о в Р.Г. Сельское расселение в Западном Закамье (вторая половина XVI — нач. XVIII в.). К., 2007; Г а л л я м Р.Г. Ясачные сотни XVI — XVIII вв. как реликт эпохи Казанского ханства // Вопр. истории. 2011. №10.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ЯСАЛМА́ КАУЧУ́К ЗАВОДЫ́**, к. *Казан ясалма каучук заводы.*

**ЯСА́ЧКА** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Бизнә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 15,8 *км*. Бассейнының мәйданы 125 *км*$^2$. Идел аръягы түбәнлегеннән, Спас р-нында ага. Елга башы Красный Вал авылыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Ширбәт авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычы сулары астында. Елганың югары агымы (якынча 10 *км* озынлыкта) язгы ташу һәм җәйге-көзге яңгыр ташкыннары вакытында гына даими; елга юлы бу участокта җәен, суының иң аз вакытындагы чорда, сазлыклы тугайда юкка чыга. Елга башының абс. биеклеге 60 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Елганың югары агымында буа бар.

**ЯСА́ЧКА** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Үтәк елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 14,5 *км*. Бассейнының мәйданы 77 *км*$^2$. Идел аръягы түбәнлегеннән, Спас р-нында ага. Елга башы Өчкүл авылыннан 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Танкеевка авылыннан 2 *км* көньяктарак. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычы сулары астында. Елга башының абс. биеклеге 75 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 3%. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*$^2$. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында — апрельнең беренчеункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Җәен, суы иң аз вакытындагы чорда елга күп кенә урыннарында кибә, һәм суы елга юлының тирәнәеп торган урыннарында (плёсларда) гына кала. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**ЯСӘВИ́** Әхмәд (Кол Хуҗа Әхмәд) (1093, Сайрам а., хәзер Казакъстан Респ-касының Чимкент ш. тирәсе – 1166, Яссы ш., хәзер Казакъстан Респ-касының Төркестан ш.), Урта Азия суфи шагыйре, ясәвийә тарикатен нигезләүче. Төрки телдә язган. Әтисе үлгәннән соң гаиләсе Яссы шәһәренә күчеп китә. Я. Яссы һәм Бохара галимнәреннән, ш.и. танылган дин галиме Йосыф Хәмәдәнидән (1140 елда вафат) белем ала. 63 яшендә дәрвиш була, хөҗрәдә яши. Я. оештырган дини мәктәп үзе исән чакта ук төрки мөселманнар арасында киң таралыш ала. Мөселман әүлиясе итеп хөрмәтләнә, каберендә табыну урынына әверелгән төрбә урнаштырылган,

анда 14 йөз ахырында Урта Азия хөкемдары Аксак Тимер әмере б-н мавзолей төзелә. Җирдәге яшәеш, хөкемдарлар һәм халык язмышы турындагы уйланулары б-н шагыйрь һәм философ буларак таныла. «Диване хикмәт» (1878) мистик, рухани эчтәлекле шигырьләр җыентыгы авторы. Аларда суфичылык гыйлеме нигезләре, төрле көндәлек киңәшләр, җирдәге яшәешнең (тормышның) фанилыгы һәм байлыкның киреләксезлеге, гаделлеккә, игелеклелеккә һәм түземлелеккә өндәү бәян ителә. Аның шигырьләренә халыкчанлык, теленә угыз сөйләшләре элементлары хас. Я. әсәрләре — барлык төрки халыкларның рухи байлыгы, алар буыннан буынга күчә килгәннәр. Татарлар арасында таралыш алалар һәм ияреп язылган шактый әсәрләр барлыкка килүгә сәбәп булалар.

Ә с ә р.: Хикмәтләр. К., 2000; Хикметы. Алматы, 2004.

*Әд.:* Я х и н Ф. Урта гасырлар татар әдәбияты. К., 2003; И ш к и н и н а Л.К. Әхмәд Ясәви хикмәтләренең лексик-семантик һәм стилистик үзенчәлекләре (Казан басмалары буенча). К., 2007; М е х т и С. Ясави и его роль в развитии ислама в Центральной Азии // Вестн. Челяб. гос. ун-та. 2007. № 23.

**ЯСӘВИ́ЕВ** Габдрахман Нурмөхәммәт улы (18.4.1940, Мамадыш р-ны Түбән Ушма а.), инженер-технолог. 1962 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Миңлебай, Ухта (Коми АССР), Вознесенский һәм Грозный (Чечен-Ингуш АССР) газ эшкәртү з-дларында эшли, 1977–84 тә «Севкавнефтегазпереработка» ҖБнең ген. директоры. 1984–86 да «Тенгизнефтегаз» идарәсе башлыгы (Казакъстан ССР), шул елларда «Тенгиз» нефть чыганагын үзләштерү башлана. 1986–90 да «Главтюменьнефтегаз» берләшмәсе башлыгының газ эшкәртү буенча урынбасары, аның җитәкчелеге елларында Көнбатыш Себер нефть иярчен газын эшкәртү 76% ка арта. 1991–97 дә «Севергазпром» ҖБнең баш технологы (Ухта ш.). СССР газ сәнәгате отличнигы (1970). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЯСӘВИ́ЕВ** Искәндәр Габдрахман улы (21.9.1971, Коми АССР, Сосногорск ш.), социолог, социол. фән. д-ры (2007). Казан ун-тының тарих ф-тын тәмамлый (1993). 1995–2015 елларда шунда ук, социол. кафедрасында эшли, бер үк вакытта, 2003–12 дә, журналистика һәм социол. ф-ты деканы урынбасары. 2015 тән «Экономика югары мәктәбе» ун-тының (С.-Петербург) яшьләр тикшерү үзәге өлкән фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре социаль проблемалар теориясенә, социаль конструктивизмга, Россия һәм чит илләрнең пенитенциар системаларына карый.

Х е з м.: Конструирование социальных проблем средствами массовой коммуникации. К., 2004; От «страны тюрем» к обществу с ограниченным причинением боли: финский опыт сокращения числа заключённых. Хельсинки, 2012; Риторика контролируемого бедствия: специфика конструирования ФСКН проблемы потребления наркотиков // Журн. исследований соц. политики. 2016. №1; «Почему уходят в ИГИЛ?»: дискурс-анализ нарративов молодых дагестанцев // Социол. обозрение. 2017. № 2 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ЯСӘВИ́ЕВ** Хәмит Нурмөхәммәт улы (26.5.1951, Мамадыш ш.), инженер-технолог, техник фән. д-ры (2005). 1973 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Ухта газ эшкәртү, Оренбург гелий з-дларында эшли, гелий җитештерү технологиясенә зур өлеш кертә (СССР Дәүләт бүләге, 1980). 1987–98 дә Сургут конденсатны тотрыкландыру з-ды директоры. 1998–99 да «Газпром» ААҖдә (Мәскәү), 2000–01 «Сургутгазпром» ҖЧҖнең ген. директоры урынбасары, 2001–06 да «Нефтехимпроект» ФҖБ директоры (Казан). РФнең атказ. газ сәнәгате хезмәткәре (1996). Мамадыш шәһәренең мактаулы гражданы.

Х е з м.: Моделирование процесса выделения изопентана из широкой фракции легких углеводов // Изв. вузов. Нефть и газ. 1998. № 2 (автордаш); Расчет высоты насадочной части колонны стабилизации газового конденсата // Вестн. Казан. технол. ун-та. 2003. № 1.

**ЯСКУ́Л** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 23 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 138 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1930 елларда нигезләнә. Оешкан көненнән — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1938 дә — 491, 1949 да — 378, 1958 дә — 417, 1970 тә — 553, 1979 да — 480, 1989 да — 150, 2002 дә — 148 кеше.

**ЯСМИ́Н**, 1) чын Я. (Jasminum), зәйтүнчәләр семьялыгыннан яфрагын коючан яисә мәңге яшел куаклар, лиана үсемлекләр ыругы. Якынча 200 төре бар. Чыгышы — Азия, Африка һәм Көньяк Америка тропиклары һәм субтропиклары. ТРда мәңге яшел лиана — Һиндстан Я.ен (самбак — J. sambac) һәм аның катмарлы төрен декоратив бүлмә гөле итеп үстерәләр. Яфраклары өчәр булып боҗрага җыелган, аларның очлары түгәрәкләнгән. Чәчәкләре 4 өлешле, нәфис, йолдызчыксыман, ак, сары, аксыл, исле, ялгыз, калкан чәчәк төркемендә. Кич б-н ачылалар. Чыбыкчадан һәм үрентеләрдән үрчи. Су яратучы үсемлек. 2) Бакча Я.е, чубушник (Philadelphus), ташкуранчалар семьялыгыннан яфрагын коючан куакчыл үсемлекләр ыругы. Якынча 70 төре бар. Чыгышы — Төньяк ярымшарның субтропик, тропик һәм уртача пояслары. ТРда декоратив үсемлек буларак эре чәчәкле чубушникны (P. Grandiflorus), сирәгрәк исле чубушникны (P. Coronaries) үстерәләр. Яфраклары каршыдаш урнашкан, бөтен читле. Чәчәкләре 4 өлешле, ак яисә аксыл, еш кына кочле исле, чукларда. Яңа җыелган яфракларында 0,1% эфир майлары бар, алар парфюмерия сәнәгатендә кулланыла. Чәчәкләрен июль-сентябрьдә кул б-н җыялар, чәйне хуш исләндерү өчен файдаланалар. Уңышы 1 *га* дан 30–100 *ц*. 2–3 елдан җимеш бирә башлый. Туры юан үрентеләре утырту чыбыклары буларак кулланыла (исеме шуннан алынган).

**ЯСМЫ́К** (Lens), кузаклылар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; ашамлык һәм терлек азыгы культурасы. Чыгышы — Көньяк-Көнбатыш Азиянең таулы районнары. Якынча 10 төре билгеле, Урта диңгез буенда, Кече Азиядә таралган. Татарстанда 1 төре — гади Я. (L. Culinaris) үстерелә. Идел буе Болгар дәүләте чорыннан билгеле. Күп бүлбе бактерияләре б-н тармакланган үзәк тамырлы. Сабагы туры яисә бераз сөрлегүчән, дүрт кырлы, биеклеге 15–80 *см*. Яфраклары катлаулы, парлы каурыйлы, очлары мыекчалы. Чәчәкләре күбәләксыман формада, ак, алсу яисә шәмәхә төстә. Кузаклары 6–20 *мм*, ромб рәвешендә, 1–3 яссыланган, линзасыман орлыклы, көрән, яшел, соры (кайвакыт рәсемле) төстә. 1000 орлыкның авырлыгы 10–82 *г*. Бөтен һәм вакланган орлыклары кулинариядә кулланыла. Я.ның өлгергән орлыкларында 23–32% аксым, 60% крахмал, 2,5% май, ш.у. $B_1$ һәм $B_2$ витаминнары туплана. 100 *кг* орлыкта якынча 120 азык берәмлеге һәм 21 *кг* үзләштерелә торган протеин бар. Яшел массасы, кибәге, саламы, вак орлыклы Я.ның бөртеге а.х. терлекләренә ашатыла. Орлыгының уңышы — 1 *га* дан 6,3–14,6 *ц*. Вегетация чоры — 65–110 көн. Чагыштырмача корылыкка чыдам. Тишемнәре кыска вакытлы кырауларга түзә (-5 °С ка кадәр). Чәчү әйләнешендә уҗымнардан һәм сызма культуралардан соң чәчелә. Иртә язда 4–5 *см* тирәнлектә чәчәләр. Түбәнге кузаклары коңгырт төскә кергәч җыялар. ТРның туфрак-климат шартлары Я. өчен уңай. ТРда чәчәргә тәкъдим ителгән сортлары: «Петровская 4/105» (1938), «Веховская 1» (2003). Кечкенә мәйданнарда үстерелә.



Ясмык.

*Әд.:* Л е о н т ь е в В.М. Чечевица. Л., 1966.

*Р.Ә.Әсретдинова.*

**Я́СНАЯ ЗВЕЗДА́** (Якты Йолдыз) авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 55 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мордвасу елгасы бассейнында урнашкан. 1930 елларда нигезләнә. Оешкан көненнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 112, 1949 да — 124, 1958 дә — 91, 1970 тә — 53, 1979 да 35, 1989 да — 20, 2002 дә даими яшәүчеләр юк.

**ЯСНИ́ТСКИЙ** Николай Николаевич (14.5.1890, Сембер ш., хәзер Ульянов — 30.10.1975, Казан), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (1924), проф. (1935). Казан. ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1914), Вятка губернасының Бемышево авылында табиб булып эшли. 1914 елдан хәрби мед. хезмәтендә. 1918 нең сентябреннән Кызыл Армия сафларында, 91 нче, 680 нче эвакуация госпитальләрендә эшли, 228 эвакуация госпитале баш табибе. 1921 дә Казан ун-тының тире-венерология клиникасында. 1926–31 дә Мәскәү–Казан тимер юл поликлиникасы та-

биб-венерологы. 1931 дән Смоленск мед. ин-тының тире-венерология авырулары каф. мөдире. 1932–38 тә Смоленск өлкә тире-венерология ин-ты директоры, 1935–39 тә Смоленск өлкә тире-венерология клиник хастаханәсе баш табибе. 1941 дән Новосибирск мед. ин-тының тире-венерология авырулары каф. профессоры. 1944 тән Казан мед. ин-тының тире-венерология авырулары каф. мөдире, бер үк вакытта, 1948–52 дә, уку-укыту мәсьәләләре буенча директор урынбасары. 1959 дан 2 нче Респ-ка хастаханәсе проф.-консультанты. Хезмәтләре тире-венерология авыруларына каршы көрәшне оештыруга, дерматозлар этиологиясен һәм аларны дәвалау ысулларын өйрәнүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лечение сифилиса висмутом // Казан. мед. журн. 1925. № 7; Роль эндокринной системы в патогенезе кожных болезней // Казан. мед. журн. 1926. № 8; Опыт применения аутовакцинотерапии в дерматологии // Казан. мед. журн. 1929. № 7/8 (автордаш); Опыт изучения щелочности крови при экземе // Казан. мед. журн. 1930. № 7 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Николай Николаевич Яснитский // Казан. мед. журн. 1976. № 3.

**ЯССЫ́ СУАЛЧАННА́Р** (Plathelminthes), түбән төзелешле суалчаннар тибы. Гәүдәсе ике яклы симметрияле, озынча, гадәттә, сырт-корсак юнәлешендә яссыланып тора. Озынлыгы 0,2 *мм* дан 18 *м* га кадәр. Киң таралганнар. Диңгез, төче су һәм җир өсте формалары бар; ирекле яшәүчеләр һәм паразитлар. Ирекле яшәүче Я.с.га ксенотурбеллидалар һәм *төкле суалчаннар*; паразитлар — аспидогастр, гирокотилидлар, *трематодалар* яки дигенетик имгеч суалчаннар, моногенийләр, амфилинидалар, *тасма суалчаннар* яки цестодалар класслары керә. Ирекле яшәүче Я.с.ның тән капламы төкле эпителиий, паразитларныкы тыгыз кутикула б-н капланган. Паразит Я.с.ның, гадәттә, гәүдәнең алгы һәм арткы очларында урнашкан берегү органнары (имгеч, капкачлар, ыргаклар һ.б.) бар. Авызы гәүдәнең корсак яки алгы өлешендә. Эчәклек гади яки тармаклы, кайвакыт бөтенләй юк. Бүлеп чыгару органы — протонефридий. Кан һәм сулыш системасы юк. Нерв системасы баш ганглийларыннан һәм алардан узучы нерв кәүсәләреннән тора, аларның 2 ян нерв кәүсәсе аеруча үсеш алган. Гермафродитлар, кайберләре аерым җенеслеләр. Татарстан терр-ясендә аеруча моногенийлар (Monogenea), трематодалар, тасма суалчаннар, төкле суалчаннар класслары вәкилләре киң таралганнар. Моногенетик имгеч суалчаннар — күбесенчә балыкларның эктопаразитлары. Арадаш хуҗадан башка гына үсәләр. Трематодаларның тереклек циклы катлаулы. Олы зат стадиясендә алар хайван һәм кеше тәненә, личинкалары — күбесенчә умырткасыз (башлыча моллюскларда) хайваннарда урнаша. Күбесе ашкайнату трактында һәм аның б-н бәйле бизләрдә — бавыр, ашказаны асты бизендә яшиләр. Татарстан терр-ясендә а.х. хайваннары өчен бавыр (Fasciola hepatica) һәм ланцетсыман (Dicrocoelium lanceatum) имгечләр куркыныч тудыра. Кеше өчен бавыр каналларында паразитлык итүче һәм описторхоз авыруы тудыручы мәче имгече (Opisthorchis felineus) куркыныч (карплар аша йогарга мөмкин). Тасма суалчаннар җенси җитлегү стадиясендә кеше һәм хайван тәнендә, личинкалары — күбесенчә буынтыгаяклыларда, әмма кайбер төрләренең личинкалары умырткалы хайваннар һәм кеше организмында яшиләр (*эхинококк*). ТР халкы өчен аеруча кеше эчәклегендә яшәүче һәм дифиллоботриоз китереп чыгаручы киң тасмач (Diphyllobotrium latum) куркыныч тудыра. Кешедә ш.у. тасма суалчаннардан *солитёрлар* (дуңгыз, үгез, кәрлә) очрый. Кыяр солитёры мәче һәм этләр өчен эпизоотик әһәмияткә ия. Карпларның күпләп үлүенә сәбәпче *каешчалар* балык хуҗалыгына зур зыян китерә.

*О.Д.Любарская.*

**ЯССЫТУГА́Й** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 10 *км* көнбатыштарак, Ютазы елгасы буенда. 2010 елда 181 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1930 елларда нигезләнә. Оешкан көненнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 405, 1949 да — 475, 1970 тә — 399, 1979 да — 345, 1989 да — 248, 2002 дә — 229 кеше.

**ЯТАГА́Н**, 1) цитрага охшаш кыллы-чиртмәле музыка уен коралы. Агач корпусы, озынча, тартма рәвешендә, озынлыгы якынча 1000 *мм*. Өске декасында җиде бакыр кыл тарттырылган; алар астында хәрәкәтчел аскуймалар бар. Алар ярдәмендә тавышның югарылык дәрәҗәсе үзгәрә. Я.ның төрләре зурлыгы, кыллар саны, тембры, тавыш акустикасы үзенчәлекләре, конструктив үзлекләре б-н аерыла. Төрки халыкларда, ш.и. татарларда (нигездә, Әстерхан һәм Оренбург татарларында, мәгълүматлар 18 йөзгә карый) кулланыла. Әлеге музыка уен коралы П.С.*Паллас* һәм И.И.*Георги* кебек тикшеренүчеләрнең хезмәтләрендә ачык тасвирлана. Я. ш.у. Себер татарларының 19 йөз ахырында В.В.*Радлов* тарафыннан язып алынган «Ак Күбек» дастанында да искә алына. Ул вакытта инде Я. сирәк кулланылыштагы музыка уен коралы була; 2) корал төре, кыска кылыч; очы бераз бөгелгән, йөзенең ике ягы да үткен ау пычагы. Аны, гадәттә, горизонталь хәлдә йөртәннәр. Төрекчә «yatagan», фарсыча «йатаған, йатақан».

*Әд.:* Ә х м ә т ь я н о в Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге. К., 2015. Т. 2.

**ЯТА́К КАНДАЛАСЫ́** (Cimex lektularius), паразит кандалалар семьялыгыннан бөҗәк. Кеше һәм күп кенә җылы канлы хайван төрләренең эктопаразиты. Киң таралган. Гәүдәсе озынча түгәрәк, яссы, 4,5 тән 8,4 *мм* га кадәр озынлыкта (җенесе һәм кан б-н туенганлыгына нисбәтле), төсе саргылттан кызгылт-көрәнгә кадәр. Авыз аппараты чәнчеп суыручы типта, түше ягына бөгелеп тора. Я.к. үсеше өчен тулы булмаган метаморфоза хас. Аталанган ана бөҗәк тәүлегенә — 1 дән 12 гә, бөтен тереклек итү чорында (1–1,5 ел) 250 дән 500 гә кадәр күкәй сала. 10–15 көннән соң (темп-рага бәйле рәвештә) алардан чыккан личинкалар 5 тапкыр кабык алыштыралар, алар өчен, кабык салган саен, кан б-н туену мөһим. Күкәйдән олы затка кадәр үсеш 1 дән 4 айга кадәр дәвам итәргә мөмкин. Олы затлар 24–48 *сәг.* саен туена, әмма бер ай (0 °С та бер елга кадәр) ач торырга да мөмкиннәр. Темп-ра 15 °С тан түбән булганда актив түгел. 45 °С та кандаланың күкәй һәм личинкалары берничә минут эчендә үлә. Я.к. — түләрәмә, кайтма тиф һ.б. йогышлы авыруларны йоктыручылар.

*В.А.Бойко.*

**ЯТИМХАНӘЛӘ́Р**, ятим балалар, фәкыйрь хатын-кызларның яшәүләрен тәэмин итү максатында оештырылган хәйрия оешмалары; картлар, гарипләр йорты. Балалар һәм бала тудыру, сөт аналары Я.е була. Патша Россиясендә күпчелек Я. императрица Мария учреждениеләр ведомствосына карый (к. *Химаячелек*). Я. Эчке эшләр министрлыгы каршында эшлиләр; аерым затлар һәм учреждениеләр тарафыннан киңәйтелгән уку программалы, кайвакыт төрле катлаулар өчен аерым Я. оештырыла; Я. рухани һәм хәрби ведомстволар каршында да була; Кешелеклелек Император җәмгыяте Я.е императрица Мария учреждениеләр ведомствосы Я.е тибында булдырыла. Я.гә киң мәгънәдә хәйрия һәм һөнәрчелек мәктәпләрен, балигъ булмаган балалар өчен төзәтү оешмаларын, физик яктан сәламәт булмаган балалар өчен ясләләр һәм оешмаларны да кертәләр.

1873 елдан Казанда Җир эшкәртү колонияләре һәм һөнәрләр Я.е җәмгыяте эшли. Җәмгыять каршындагы Я.дә элек күп очракта караклык б-н шөгыльләнгән 11–18 яшьлек тәрбияләнүчеләр башлангыч мәктәп күләмендә гомуми белем предметлары буенча укытыла, ш.у. агач эшкәртү, слесарьлык һөнәрләренә өйрәнәләр; тәмамлаучылар Җәмгыять остаханәсендә эшлиләр. Казанда 1875 нең 24 ноябрендә төзәтү һөнәр ятимханәсе ачыла. 1886 да сәүдәгәр И.Н.Журавлёв акчасына 268 кешелек төн кунып чыгу ятимханәсе оештырыла. 20 йөз башында Казан рус хатын-кызлары җәмгыяте каршында *Кешелеклелек Император Казан ярлыларга ярдәм итү комитеты* эшли, аның Хатын-кызлар бүлеге 1876 да ачыла. Бүлектә хуҗалык-кул эшләренә өйрәтү мәктәбе, йорт-җирсез хатыннар һәм балаларга вакытлыча сыену урыны, аш-су сәнгатенә өйрәтү өчен аш пешерү урыны була. 1893 тә Казанда 5 ятимханә эшләп килә: *Николай исемендәге балалар ятимханәсе* (117 кыз бала), Александр исемендәге ятимханә (115 кыз бала), *Мөселман балалар ятимханәсе* (31 ир бала), җинаять кылган кече яштәге балалар өчен ятимханә (35 ир бала), Ярлы һәм авыру балаларга ярдәм итү җәмгыяте ятимханәсе (35 кыз һәм ир бала), ш.у. ятимханәле балалар хезмәт сөю мәктәбе.

Инвалидлар һәм картлар йортлары Казанда 18 йөз башыннан ачыла башлый; алар өчен акча Экономия коллегиясеннән бүленеп бирелә (1739 да Казанда 5 шундый йорт була). Алар, гадәттә, монастырьлар каршында оештырыла. 1758 дә — Казанда отставкада-

гы штаб- һәм обер-офицерлар, 1760 та отставкадагы, яраланган һәм гарипләнгән солдатлар өчен инвалидлар йорты булдыру турында указ чыга. 19 йөз башында Җәмәгать тәрбиясе приказы карамагында тимерчелекләр акчасына тотылган картлар йорты, тәрбия йорты, акылга зәгыйфьләр йорты, хастаханә була. 1848 дә Ложкин картлар йорты ачыла, анда авырулар, гарипләр һәм картлар тәрбияләнә (ачылган елда — 43, 1887 дә 500 кеше). 1872 дә Казан рус мещаннар җәмгыяте каршында ачылган картлар йортында картлар да, 15 яшькәчә ятимнәр дә була (төрле елларда 25 тән 75 кә кадәр кеше тәрбияләнә). 1889 да картлар һәм инвалидлар йортларында һөнәр класслары оештырыла; аларны тәмамлаучылар һөнәр һәм сәүдә-сәнәгать оешмаларында эшкә урнаша. Малайлар итек тегү б-н шөгыльләнә, кызларны тегәргә, чигәргә, бәйләргә өйрәтәләр. 1880 дә Крупениковларның ярлы тол хатыннар һәм дин әһелләренең ятим балалары йорты ачыла (аңа акчаны сәүдәгәр И.С.Кривоносов бирә). 1895 тән дворяннар өчен Александр-Чемисов картлар йортында төрле дәрәҗәдәге һәм яшьтәге, терелә алмаслык авырулы хатын-кызлар өчен сыену урыны булдырыла. Казан Богородица хатын-кызлар монастырендa дин әһелләренең ятим кызлары тәрбияләнә. 1893 тә Казанда 11 гарипләр һәм картлар йорты (мещаннар җәмгыятенеке һәм губерна земствосыныкы) була һәм анда 1355 кеше тәрбияләнә.

1917–18 дә барлык хәйрия оешмалары, Я. ябыла. Совет хакимияте чорында караучысыз калган балалар өчен дәүләт тарафыннан балалар йортлары, интернатлар һ.б. оештырыла.

1990 елларда ятимнәргә ярдәм киң һәм яңа формаларда күрсәтелә башлый. 1994 тә Раифа ирләр монастыре каршында караучысыз калган балалар өчен ятимханә оештырыла, 1998 дә Казан администрациясенең Балалар һәм яшьләр эшләре ком-тының 3 тән алып 15 яшькәчә балалар өчен социаль-тернәкләндерү үзәге ачыла, 1999 да Казан архитекторы Р.Шәйхетдинов хосусый акчаларга караучысыз калган балалар өчен ятимханә оештыра. Күп ятимнәрне гаиләләргә тәрбиягә алалар.

*Әд.:* Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К.,1998; Загоскин Н.П. Спутник по Казани. К., 2005; Брокгауз Ф.А., Ефрон И.А. Энциклопедический словарь. СПб., 1893. Т. 11. *И.А.Новицкая.*

**ЯТМА́С-ДУСА́Й** авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 29 *км* көньяктарак, Мишә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 348 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1619 дан Качкынчы авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Костенеево, Ятмас исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 963,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 58 ир-ат; 1859 да — 320, 1897 дә — 458, 1908 дә — 537, 1920 дә — 519, 1926 да — 552, 1949 да — 445, 1958 дә — 406, 1970 тә — 478, 1979 да — 442, 1989 да — 355, 2002 дә — 366 кеше.

**ЯТУ́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мөшеге елгасы буенда. 2010 елда 61 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1713 тән билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Мушуга-Тамак, Мушугинское Устье исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә, Иштирәк бакыр эретү з-дында ялланып эшли, 1773–75 тәге Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында Я.да мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 222 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 53, 1816 да — 22, 1834 тә — 30 ир-ат; 1859 да — 89, 1870 тә — 90, 1906 да — 266, 1913 тә — 235, 1920 дә — 241, 1926 да — 225, 1938 дә — 210, 1949 да — 225, 1958 дә — 213, 1970 тә — 178, 1979 да — 123, 1989 да — 64, 2002 дә — 67 кеше.

**ЯУЛАШТАУ́** (Түбән Мишәбаш) авылы, Саба р-нында, Байлар Сабасы авылыннан 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы (Кече Мишәнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 451 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1778 дән билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Евлашева, Евластова исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да мәчет (1871 дә төзелә; хәзергесенең бинасы 1922 дә төзелә; архит-ра истәлеге), мәктәп, тегермән, вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1106,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 69 ир-ат; 1859 да — 502, 1897 дә — 640, 1908 дә — 671, 1920 дә — 714, 1926 да — 653, 1938 дә — 626, 1949 да — 550, 1970 тә — 509, 1979 да — 484, 1989 да — 440, 2002 дә — 455 кеше.

**ЯУ́Р** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Чирмешән елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 15,6 *км*, ТР чикләрендә — 7,4 *км*. Бассейнының мәйданы 76,3 $км^2$. Идел аръягы түбәнлегеннән ага. Елга башы Самара өлкәсе терр-ясендәге урман массивында, тамагы Чирмешән р-ны Чирмешән авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 94 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Я.ның 0,3 һәм 10,2 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,04 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЯУ́Ш** бәк (Яуш би ?) (? — 1552 дән соң), Арча бәге. Казанны Иван IV гаскәрләреннән саклаганда (к. *Казанның яулап алынуы*) Я. морзалар Япанча һәм Шунак би б-н бергә рус гаскәрләренең тылында хәрәкәт итә.

*Әд.:* Алишев С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV — XVI вв. К., 1995.

**ЯУША́Н**, вероника (Veronica), сыраҗчалар семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләннәр, кайвакыт ярымкуакчыклар ыругы. 300 гә якын төре билгеле, башлыча, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында таралганнар. ТР терр-ясендә 15 төре бар: имәнлек Я.ы (V. chamaedris), дарулы Я. (V. officinalis), киң яфраклы Я. (V. teucrium), чишмә Я.ы (V. anagallis) һ.б. Урман, болын, елга ярлары буенда үсә. 10 нан 1,5 *м* га кадәр биеклектәге, шома яки төкчәле сабаклы үсемлек. Сабагы туры, сирәк кенә яткын яки шуышма. Яфраклары бөтен, йомырка- яки ланцетсыман. Чәчәкләре зәңгәр, шәмәхә, чукка җыйналган, сирәк кенә ялгызы яфрак куентыгында. Җимеше — ике оялы тартмачык. Май-августта чәчәк ата. Орлыктан үрчиләр. Халык медицинасында дарулы Я., имәнлек Я.ы, чишмә Я.ының җир өсте өлешләреннән ясалган чәй, төнәтмә, согы бронхит, йөткерү, бөер һәм бәвел куыгы авыртулары вакытында файдаланыла. Күп кенә төрләре: озын яфраклы Я. (V. Longifolia), басу Я.ы (V. agrestis), яткын Я. (V. prostrata) һ.б. — терлек азыгы; кайберләре: басу Я.ы, фарсы Я.ы (персидская) (V. tournefortii) — чүп үләннәре. Кайбер төрләрен: ак Я.ны (V. Incana), киң яфраклы Я.ны декоратив үсемлек буларак үстерәләр.



**ЯУ́ШЕВ** Әхмәт Мөхәммәт улы (25.12.1925, Казан), сәнәгый җитештерүне оештыручы, РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1985). Казан авиация техникумын (1943), Казан авиация ин-тын (1949) тәмамлый. 1941–52 елларда Казанның 16 нчы моторлар төзү з-дында эшли. 1952–58 дә Казан авиация ин-тында укыта. 1958 дән Казан компрессорлар з-дында: баш технолог, баш инженер. 1966–87 дә Казан «Электроприбор» з-ды директоры. Я. җитәкчелегендә пр-тиедә реконструкция уздырыла; двигательләрнең температурасын һәм көчәнешен, самолётларның кабиналарында һәм салоннарында кондиционерлауны автомат көйләү һәм контрольдә тоту системаларын, МиГ-23, МиГ-27 һ.б. самолётлар б-н автомат идарә итү системаларын эшләп чыгару үзләштерелә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ЯУ́ШЕВ** Марат Фәрид улы (9.3.1965, Сәмәрканд ш.), фтизиатр, мед. фән. д-ры (2004), проф. (2009). Проф. А.А.Визель шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1988), Респ-ка туберкулёз диспансерында эшли. 1991 елдан Казан мед. ин-тының фтизиопульмонология кафедрасында (1997 дән доцент), бер үк вакытта, 1998 дән, ин-тның уку-укыту бүлеге башлыгы. Хезмәтләре үпкә туберкулёзы диагнозы куелган авырулар-да сулау механикасы үзгәрешләрен, лимфоцитлар апоптозы процессларының вентиляция тайпылышлары б-н үзара бәйләнешен, туберкулёз б-н бәйле обструктив синдромны дәвалаганда кортикостероидлар куллануның нәтиҗәлелеген өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Курс туберкулёза в вопросах и ответах: В 2 ч. К., 1996 (автордаш); Сравнительное исследование апоптоза лимфоцитов с вентиляционными нарушениями у больных туберкулёзом легких. Проблемы туберкулёза и болезней легких. 2004. № 5 (автордаш).

**ЯУ́ШЕВ** Мөхәммәт Вәли улы (12.11.1893, Казан — 25.2.1969, шунда ук), скрипкачы. 1912–14 елларда Гуммерт мәктәбеннән скрипкачы Руссодан дәресләр ала. 1912 дән милли инструменталь ансамбльләр составында чыгыш ясый. 1922–37 дә Татар акад. театрында һәм Радиоком-тта, 1939–59 да Татар опера һәм балет театрында оркестрлар музыканты һәм нота китапханәләре мөдире. Татар музыкасы яңгыратылган концертларда катнаша, татар композиторлары б-н язышa һәм аларның оркестр өчен иҗат ителгән әсәрләренең кульязмаларын саклауны тәэмин итә. Татар музыкасы тарихына караган күп кенә мәкаләләр авторы. Татар концертлары бирүгә нигез салучыларның берсе.

**ЯУ́ШЕВ** Нәүширван Шириаздан улы (1885, Уфа губ., Бәләбәй өязе Мең Тал а. — 10.11.1917, Ташкент), сәяхәтче, публицист, җәмәгать эшлеклесе. «Галия» мәдрәсәсендә (Уфа ш., 1911 елга кадәр) укый. 1911–13 тә Казакъстанда укытучылык итә. 1913–17 дә Урта Азия, Көнчыгыш Төркестан шәһәрләре буйлап сәяхәттә була, «Вакыт» г-тасында һәм «Шура» ж-лында юл язмаларын бастыра. 1917 дәге Февр. рев-циясеннән соң «Олуг Төркестан» (Ташкент) г-тасы хезмәткәре. Мәкаләләре Россиянең Көнчыгыш төбәкләрендәге һәм Көнбатыш Кытайдагы төрки телле халыкларның теле, әдәбияты һәм мәдәниятенә багышлана.

Х е з м.: Алты шәһәр тарихыннан бер парча // Шура. 1916. № 18–24; 1917. № 3, 10.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Нәүширван Яушев: Некролог // Вакыт. 1917. № 2290; Ә х м ә т җ а н о в М. Татар әдәбияты тарихына яңа исемнәр // Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш. К., 1987; Р ә м и И., Д а у т о в Р. Әдәби сүзлек. К., 2001.

**ЯУ́ШЕВ** Равил Мөхәммәтҗан улы (14.1.1925, Казан — 13.8.2014, Лениногорск), тренер (гандбол), ТАССРның атказ. физик культура хезмәткәре (1985), ТРның атказ. тренеры (2005). 1968 елда РСФСР Үзәк тренерлар мәктәбен тәмамлый (Мәскәү өлкәсе Малаховка штп). 1946–59 да Калинин исем. Казан төгәл машиналар төзү, (1959–83 тә «Приборлар» 1970 тән «Радиоприбор» АҖ) з-дларының физик культура коллективларында инструктор булып эшли, 1983–2001 дә 13 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер-укытучы (Казан). Бер үк вакытта, 1965–83 тә, гандбол буенча «Электрон» хатын-кызлар командасында тренер, команда РСФСР чемпионатларында («А» классы) 1965,1967 дә — бронза, 1966 да көмеш медальләр ала. Шәкертләре арасында — Л.Е.*Шубина*, СССР чемпионатларында медаль алучылар Н.Осетинская, О.Селезнёва, Россиянең атказ. тренерлары Л.М.Каюрова, Н.Г.Бәдретдинова. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЯУ́ШЕВ** Рөстәм Исмәгыйль улы (17.7.1937, Үзбәкстан ССР, Ташкент ш. — 20.7.2017, Мәскәү), график, нәкышьче, Россия САнең хакыйкый әгъзасы (1997), РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1997). 1950 елларда Ташкентта рәссам Б.Урманче б-н очраша, бу күрешү иҗат юлын сайлауга этәргеч бирә. Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), Петропавловск-Камчатский шәһәренә китә. 1971–74 тә Мәскәүдә, СССР СА иҗат остаханәсендә Е.А.Кибрикта укый. 1974 тән Мәскәү график сәнгать комб-тында, бер үк вакытта, 1982 гә кадәр, СССР Эчке эшләр министрлыгының рәссамнар студиясендә эшли. 1993–96 да Красноярск сәнгать ин-ты ректоры, проф. (1995). 2007 дән Мәскәү шәһәр пед. ин-тының рәсем һәм графика кафедрасында укыта. Рәссамнар берлеге (1964), Мәскәү татар рәссамнарының «Рәссам» берлеге (2004), Рерихлар исем. Россия-Һиндстан сәнгать клубы (1996) әгъзасы.

Күпчелеге Камчатка темасына багышланган, «Камчатка киңлекләрендә» (1971), «Сопкалар арасында», «Яз аһәңнәре» (икесе дә — 1970 еллар), «Медный атавы» (1981), «Тыныч киңлекләр» (1982–85), «Камчатка җире» (2011) һ.б. серияләрне эченә алган станлы графика әсәрләре (офорт, темпера, карандаш, гуашь) иҗат итә. 1996 дан ш.у. нәкышь б-н шөгыльләнә, Чукоткада, Себердә иҗат командировкаларында була. Рәссамнар берлегенең Иҗат экспедицияләре бюросы составында Һиндстанда, Индонезиядә, Франциядә, Испаниядә, Филиппинда эшли. «Һиндстан»(1996–97), «Уйланулар» (2004–06) офорт серияләре, «Испания» (1998–99) сериясе; нәкышь жанрында «Президент полкының каравыл алмашы» диптихы, «Мәскәү елгасы», «Лужков күпере» (барысы да — 2006–07), «Гомернең өч фасылы. Автопортрет», «Диңгез шавы», «Һиндстан гыйбадәт кылучылары», «Гыйбадәт кылучылар һәм изге сыерлар» (барысы да — 2009) нәкышь картиналары (киндер, оргалит, акрил) авторы.

1964 тән күпсанлы станлы графика әсәрләре: 2–6 нчы «Совет Россиясе», 2–6 нчы «Совет Ерак Көнчыгышы» (Мәскәү); бөтенсоюз — «Совет хакимиятенең 50 еллыгы» (1967), «СССР — безнең Ватаныбыз» (1973) (Мәскәү); халыкара — «Яңа кеше — яңа дөньяның хуҗасы» (Берлин, 1967) күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре Европа, Азия, Африка илләрендә оештырылган 50 гә якын күргәзмәгә куела. Шәхси күргәзмәләре 1989, 2007 дә (Мәскәү), 1993 тә (Красноярск), 2008 дә (О.Р.Яушева б-н, Индонезиядә, Бали утравы), 2010 да, 2014 тә (О.Р.Яушева һәм З.М.Яушева б-н, Мәскәү), 2012 дә (Казан) уздырыла.

Әсәрләре Мәскәү заманча сәнгать музеенда, Революция музеенда, Хабаровск, Петропавловск-Камчатский, Владивосток, Красноярск, Иркутск һ.б. шәһәрләрдәге, чит илләрдәге (АКШ, Япония, Кытай, Төркия, Франция) шәхси коллекцияләрдә саклана. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ш а н т ы к о Н.Н. Здесь начинается Россия // Художник. 1970. № 11; Х а б а р о в а М.В.





Р.И.Я у ш е в. 1. «Декабрьдә чик сакчылары янында». 1975; 2. «Матур нерка балыгы». 1985.

Рустам Яушев. Альбом. Л., 1988; Кантор А.М. Рустам Яушев. Каталог. М., 1989; Яушев Р.И. Рустам Яушев. Альбом. М., 2007.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**Я́УШЕВЛАР**, татар бәкләре нәселе. Нәселгә нигез салучы Арча бәге Яуш әле Казан яулап алынганга (1552) кадәр үк рус патшасында хезмәттә була. 17 йөзнең 1 нче яртысында Я. рус рәсми документларында кенәзләр буларак күрсәтелә. Рус патшасы Михаил Фёдоровичның 1628 елгы грамотасында Казан йомышлы морзасы Семеней кенәз Яуш улы Багишевка кенәз титулы «аның бабасы кенәз Яуш, һәм аның абзасы кенәз Иванай, һәм аның атасы кенәз Багиш хезмәтләре өчен, һәм аның үзе — Семеней хезмәте өчен...» бүләк итеп бирелүе турында белдерелә. 1666 да кенәз Я.га алар Зирекле авылына нигез салган җир (хәзер Яңа Чишмә р-нының Югары Зирекле а.), ш.у. Тирсә волостендагы Кама елгасы буйлап һәм Җөри даругасындагы Зәй елгасы буйлап сузылган җирләр бүләк ителә. 17 йөздә Богдан Яушевның биләмәләре Казан өязендәге — 11, Яштирәк (Иштирәк) Яушевныкы — 8, Кадермәт Яушев биләмәләре 6 авылда урнашкан була. 1713 тә патша Петр I фәрманы буенча, чукындырудан баш тарткан өчен, Я.ның биләмәләре патшага тартып алына, аларга Казан губернасы буенча җан башыннан түләү салына. Шуның б-н бергә мөселман крепостной крәстияннәр элеккечә Я.ныкы булып исәпләнә. 1730 елларда Я. үз биләмәләрен һәм крепостной крәстияннәрен актив рәвештә сата башлыйлар: 1733 тәге иялек грамотасы буенча, Я. Тирсә волостендагы җир биләмәләрен һәм крәстияннәрен Котлыгъмөхәммәд *Тәфкилевкә* 3 мең сумга, 1739 да Нугай даругасының Тамгачы авылындагы 32 чирек җирне һәм крепостной крәстияннәрне Сөләйман Уркинга саталар. 1762 дә Я. нәселенең бер өлеше Бәләбәй өязенең Арслан авылына (хәзер Башкортстан Респ-касы терр-ясендә) күчеп утыра. 1796 да Зирекле һәм Арслан авылларында яшәгән морза Я. үзләренә дворяннлык титулын кире кайтаралар. Идарә итүче Сенатның 1844, 1854, 1862, 1864 һәм 1873 еллардагы билгеләмәсе буенча кенәз Я. нәселе (губерна секретаре Фәйлүш Хәсән улы һәм аның уллары Исламгәрәй, Солтангәрәй һәм Сәетгәрәй; Хөсәен Хәсән улы һәм аның улы Нургали; Мөхәммәтрәхим Хәсән улы; Харилбәшир Әбдрәшит улы һәм тагын унбер гаилә), татар кенәзләре дип аталу хокукы б-н Нәселләр китабының 6 нчы өлешенә кертелеп, борынгы дворяннар дәрәҗәсендә раслана. 1877 дә Арслан авылында бәк Я. нәселеннән 87 ир-ат яши.

*Әд.:* Мустафина Д. Служилые мурзы Яушевы в XVI — XVII вв. // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2001. № 1/2; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

**Я́УШЕВЛАР**, Троицк сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре, җәмәгать эшлеклеләре. Фаразланганча, сәүдәгәр Я. татар бәкләре *Яушевлар* нәселеннән башлангыч ала. 18 йөзнең 2 нче яртысында — 19 йөз башында Казан губернасыннан Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе һәм Оренбург губернасының Троицк өязе терр-яләренә күчеп утыралар. Сәүдәгәр Я. нәселеннән иң танылганнары: 1) **Гайса Мөхәммәдйосыф улы** (? – 1870), 1 нче гильдия сәүдәгәр. 1852–59 елларда Троицк шәһәрендә күн һәм сабын кайнату з-дларына нигез сала. 1850 елларда Троицк шәһәр ратушасы ратманы. 1839 да Троицк сәүдәгәрләре б-н бергә шәһәрдә Гостиный двор ачу өчен тырыша. 1863 тә 3 нче җамигъ мәчет төзелешенә зур күләмдә акча иганә кыла. 2) Аның балалары: **Әхмәтҗан Гайса улы** (1818–5.2.1875), 1 нче гильдия сәүдәгәр, сабын кайнату з-ды хуҗасы. 1872–75 тә Троицк шәһәр думасы гласные; **Мөхәммәдлатыйф Гайса улы** (1847–1885, Троицк), 1 нче гильдия сәүдәгәр. 1880 нән Троицк шәһәр думасы гласные. 3) Бертуганнар: **Габделвәли Әхмәтҗан улы** (12.3.1840, Троицк — 13.9.1906, шунда ук), 1 нче гильдия сәүдәгәр. 20 йөз башында Орск, Троицк, Чиләбе, Ташкент шәһәрләрендә а.х. продукциясен эшкәртү буенча 5 пр-тие хуҗасы була. 1894–95 тә аның акчасына Троицкида 6 нчы җамигъ мәчет һәм аның каршында уку йортлары комплексы төзелә. 1888 дән Троицк шәһәр думасы гласные. Троицк мөселман хәйрия җәмгыяте рәисе (1901 дән). Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае эшендә катнаша (1905, Түбән Новгород ш.). Аның кызы **Фатиха** (кияүдәге фамилиясе Аитова) 1897 дә үз хисабына Казанда ярлы гаиләләрдән чыккан кыз балалар өчен башлангыч мәктәп, аннары татар хатын-кызлары гимназиясе ача (к. *Аитова Фатиха гимназиясе*); **Муллагали Әхмәтҗан улы** (? – ?), 1 нче гильдия сәүдәгәр, коммерция советнигы. 1910 да Троицк өязендә 1131 дис. җир били. 1814–17 дә Троицк өяз земство җыены гласные. Троицк мөселман хәйрия җәмгыяте рәисе (1907–17). 1909 да — Кустанай шәһәренең Мөселман хәйрия җәмгыятен, 1914 тә башлангыч уку йортларында тәрбияләнүчеләргә химаячелек итү өчен Троицк «Өчьяфрак» («Трилистник») җәмгыятен оештыручыларның берсе. Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае эшендә катнаша (1906, С.-Петербург). Троицкида «Вазифа» мөселман ир-ат укытучылар семинариясен ачуга акчалар (1915), С.-Петербургта җамигъ мәчет төзелешенә 1 мең сум акча иганә кыла. 1917 дән Владивосток шәһәрендә яши, соңрак Харбин шәһәренә (Кытай) күчә; **Мөхәммәдшәриф Әхмәтҗан улы** (? – 1906), 1 нче гильдия сәүдәгәр. Оренбург төрмәләр буенча химаячелек ком-тының Троицк өяз бүлеге директоры. 1893 тә бертуганнар «Г.Ә. Яушев һәм бертуганнар» сәүдә йорты оештыралар, аның үзәк конторасы Троицкида, ф-ллары Мәскәүдә, Чиләбедә, Кустанайда, Ташкентта, Варшавада (Польша патшалыгы), Голҗа (Кытай), ш.у. Оренбург губернасының Кучкар посёлогында, Җидесу өлкәсенең Токмак авылында була. Азык-төлек, тукымалар б-н сату итәләр (1895 тә тукымалар сату буенча еллык әйләнеш 4.3 млн. сум тәшкил итә). 1910–13 тә Кустанайда, Ташкентта, Троицкида һәм Чиләбедә сәүдә пассажлары төзиләр. Троицкида күп кенә пр-тиеләр (терлек мае эретү һәм йон юу биналары, сугым урыннары, чәй төрү ф-касы), Оренбург губернасында зур җир биләмәләре, Сыр-Дәрья өлкәсендә мамык плантацияләре һәм 2 мамык чистарту з-ды хуҗалары булалар. Хәйриячелеккә, мәгариф үсешенә, мөселман дини учреждениеләре төзелешенә һ.б.га шактый күләмдә акчалар иганә кылалар. Троицкида алар акчасына «Сөембикә» мөселман кыз балалар мәктәбе ачыла, хатын-кызлар мәдрәсәсе төзелә. 4) Бертуганнар: **Муллахмәт Латыйф улы** (?–?) һәм **Муллaмөхәммәт Латыйф улы** (?–?), 1 нче гильдия сәүдәгәрләр, нәселдән күчмә мактаулы граждданнар. Троицкида «Яушев Л.Г. варислары» сәүдә йорты оештыралар, 1897 дә күн з-ды ачалар. Троицкида һәм Ташкентта мануфактура товарлары б-н сәүдә итәләр. (1895 тә сәүдә әйләнеше якынча 500 мең сум тәшкил итә). 5) **Мөхәммәтгали Габделвәли улы** (?–?), сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе. Троицкида мануфактура товарлары б-н сату итә. Троицк өязендә 811 дис. җирләре була. 1911–13 тә Троицк мөселман хәйрия җәмгыятенең идарә әгъзасы, 1914–17 дә Троицк шәһәр думасы гласные. Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае эшендә катнаша (1906, С.-Петербург). 6) **Габделлатыйф Мөхәммәдшәриф улы** (?–?), 1 нче гильдия сәүдәгәр. Троицк мөселман хәйрия җәмгыятенең идарә әгъзасы (1911–13). Троицкида «Нәҗат» түләүсез мөселман китапханәсе ачуны башлап йөрүчеләрнең берсе, Троицк мәгърифәт тарату җәмгыяте рәисе. Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае эшендә катнаша (1917, Казан), финанс комиссиясе составына сайлана. Милләт Мәҗлесе депутаты, финанслар ведомствосы әгъзасы. Окт. рев-циясеннән соң, Я. гаиләсенең күпчелек вәкилләре чит илгә эмиграциягә китә. Троицк, Чиләбе һ.б. кайбер шәһәрләрдә, архит-ра истәлеге буларак, сәүдәгәр Я.ның сәүдә йортлары бинaлары сакланып калган.

**ЯУШИРМӘ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 26 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Бахта елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 664 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигезләнә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Калеева, Кече Бахта исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт һәм алпавыт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртә, терлекчелек, йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.дә 3 мәчет, вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3677 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Кызылъяр волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 210 ир-ат;1859 да — 1372, 1897 дә — 1964, 1908 дә — 2121, 1920 дә — 2116, 1926 да — 2860, 1938 дә — 2085, 1949 да — 1367, 1958 дә — 1439, 1970 тә — 1500, 1979 да — 1124, 1989 да — 723, 2002 дә — 739. Я.дә язучы, җәмәгать эшлеклесе Г.Исхакый туган (музей).

**ЯУШЫЕ́К** (Яушыйк) авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2010 ел-

да 84 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорында нигезләнә. Беренче атамасы — Яулышыек. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.та мәчет, мәдрәсә, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1527 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Астраханка волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 52, 1859 да — 217 ир-ат; 1897 дә — 718, 1908 дә — 884, 1920 дә — 950, 1926 да — 967, 1938 дә — 592, 1949 да — 428, 1958 дә — 405, 1970 тә — 330, 1979 да — 213, 1989 да — 137, 2002 дә — 110 кеше.

**ЯҮГИ́ЛДИНА** Зилия Мохтар кызы (9.7.1960, БАССРның Октябрьск ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2008), проф. (2011). 1984 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. 1982 дән Казан мәктәпләрендә музыка һәм җыр дәресләре алып бара. 1992 дән Казан пед. ин-тының муз. тәрбия нигезләре кафедрасында, 1998–2007 дә һәм 2010 нан музыка теориясе һәм тарихы кафедрасында, 2007–08 дә сәнгать белеме һәм тарихы каф. мөдире. 2008 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тының татар муз. иҗат каф. мөдире. 2010 нан Татар гуманитар пед. ун-тының сәнгать белеме ф-ты деканы. 2011 дән Казан ун-тының сәнгать һәм дөнья матур әдәбияты теориясе каф. мөдире. Хезмәтләре Татарстанда эстетик тәрбия, музыка белеме тарихы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Музыкально-эстетический интерес младших школьников: вопросы теории и практики. К., 2002; Музыкальное образование в общеобразовательных учреждениях Казанской губернии (вторая половина XVIII — начало XX вв.). К., 2007; Развитие общего музыкального образования в Татарстане (XX в.). К., 2007.

**ЯФА́РОВ** Бәкер Гариф улы (14.3.1888, Самара губ., Яңа Үзән р-ны Алтата а. – 6.6.1954, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1950). «Зәһидия» (Оренбург ш., 1902–12), «Галия» (Уфа, 1915 елга кадәр) мәдрәсәләрендә укый. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1931). 1924 елга кадәр укыта, Саратов өлкәсенең Дергачи р-ны халык мәгарифе бүлегендә эшли, 1930 дан Татар коммунистлар ун-тында, 1937–52 дә Казан пед. ин-тында укыта. Хезмәтләре 10–14 йөзләрдә Кама-Идел болгарлары әдәбиятына, Мәхмүд Болгариның «Нәһҗ әл-фәрадис» кульязмасын өйрәнүгә карый. Урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр, хрестоматияләр, уку-укыту программалары авторы.

*Р.Р. Мусабәкова.*

**ЯФА́РОВ** Лотфи Исмәгыйль улы (1900, Оренбург губ., Калинино волосте Кулатов-Яфаров а. — 1983, Казан), тел галиме, филол. фән. канд. (1956). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1930), Татар коммунистик ун-тында эшли, 1935 елдан ТАССР Мәгариф халык комис-тында. 1939 дан Актүбә шәһәрендә (Казакъстан ССР): 4 нче урта мәктәп директоры, 1945 тән Актүбә укытучылар ин-тының татар теле каф. мөдире. 1951 дән Казан ун-тында, 1954–65 тә Казан пед. ин-тының татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире. Хезмәтләре татар теленең тарихи фонетикасы, орфографиясе, пунктуациясенә карый. Урта мәктәпләр өчен татар әдәбиятыннан дәреслекләр авторы.

Х е з м.: Татар теле үсештә. К., 1955.

*М.Ә.Сәгыйтов.*

**ЯФӘ́СЕВ** Габдрәшид Ярулла улы (15.4.1944, Ташкент), техника фән. д-ры (1990). Ташкент ун-тын тәмамлый (1969), Ташкентта эшли: Үзбәкстан ССР ФАнең Физика-техника ин-тында (1977 дән тәҗрибә КБсы башлыгы); 1986 елдан «Академприбор» фәнни-җитештерү берләшмәсенең электрон приборлар төзү бүлеге мөдире, бер үк вакытта, 1986–93 тә, РФА В.И.Вернадский исем. Геохимия һәм аналитик химия ин-тының махсус лаб-ясе җитәкчесе. 2000 дән Калининград шәһәрендә: «Балтика» инновациялә-технол. үзәге директоры һәм Балтыйк балыкчылык флоты академиясенең инновацион идарәсе башлыгы (2006 дан). Бер үк вакытта Балтыйк тикшеренү үзәге директоры. Хезмәтләре космик нурларны, идарә ителүче термотөш синтезын тикшерү, йөрткечләр бортында коргылар барлыгын дистанцион зондлау өчен махсус аппаратура һәм җиһазлар булдыруга, аларны радиацион экологиядә һәм радономониторингта куллануга карый. Мегаватт егәрлегендәге зур кояш мичен проектлый һәм төзи. Махсус кулланышлы приборлар өчен төрле материаллардан ярымүткәргечле детектор системаларын булдыру принципларын, серияле ярымүткәргечле материаллардан югары нәтиҗәле һәм киң функцияле детектор системаларын эшли. Үзбәкстан ССР терр-ясендәге радон кырлары картасын төзи. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кремний-литиевые детекторы ядерного излучения. Таш., 1981 (автордаш); Твёрдотельный спектрометр заряженных частиц на основе Si-фотодетектора и сцинтиллятора Cs (Tl) // Прикладная ядерная спектроскопия. М., 1985. Вып. 12 (автордаш); Подготовка кадров резерва Правительства субъекта Российской Федерации: вопросы методики и организации // Экономика и управление. 2009. № 9 (автордаш).

**ЯФӘ́СЕВ** Гадел Габделмәлик улы (21.2.1951, Фрунзе), физика-матем. фән. д-ры (1992), проф. (2007). 1974 елда Лениград ун-тын (хәзер Петербург ун-ты) тәмамлый, шунда ук, Физика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (1974 тән), каты җисем электроникасы каф. профессоры (1993 тән). Хезмәтләре ярымүткәргечләр өслеге, түбән үлчәмле квант системалары физикасына һәм наноэлектроникага карый. Ярымүткәргеч-электролитның фазаара чигендәге электрон процессларын тикшерү алымнарын эшли, бүлмә темп-расы шартларында ирекле коргы йөрткечләренең үлчәмле квантлашуы күренеше мөмкинлеген күрсәтә. Квант челтәрләре теориясенең физик нигезләрен булдыра.

Х е з м.: Физико-химические основы микроэлектроники конструирования и технологии РЭА и ЭВА. Махачкала, 1987 (автордаш); Физика поверхности полупроводниковых электродов. СПб., 2003 (автордаш); Field-Effect in Semiconductor-electrolyte interfaces: Application to Investigations of Electronic Properties of the Semiconductor Surfaces. Prinston, 2006 (автордаш).

**ЯФРАГАШАРЛА́Р** (Chrysomelidae), төрле азык б-н тукланучылар асотрядыннан коңгызлар семьялыгы. Якынча 40 мең төре, Россиянең Европа өлешендә — 1,4 меңгә кадәр, Татарстан терр-ясендә 300 гә якын төре билгеле. 1 *см* га кадәр озынлыктагы кыска юан, сирәк кенә озынча гәүдәле кечкенә яки уртача зурлыктагы коңгызлар, мыекчаларының озынлыгы гәүдәсенең яртысы кадәр, барлык аякларының 3 нче буынтыгы ике калаклы яки уемтылы. Гәүдәсе төрле, еш кына металлсыман төсмерле ачык төстә. Үсемлекләр б-н тукеналар. Коңгызлар, гадәттә, яфракларда, чәчәкләрдә, ара-тирә туфракта очрый. Личинкалары тышкы тирәлекнең төрле шартларында тереклек итә. Күпчелеге ачык ландшафтларда яши һәм яфраклар б-н туена, күбесе (кайбер Galerucinae, Halticinae) тамырларда — туфракта җитлегә, кайберләре — яфрак тукмаларында, ботакларның үзәгендә (кайбер Halticinae) яки су асты үсемлекләрендә (Donaciinae) җитлегә. Башка төрләренең личинкалары туфракта, үзләренең кипкән экскрементларыннан ясалган каты тышчаларда яши һәм үсә барган саен алар аны зурайталар, үсемлек детритлар б-н туеналар (Cryptocephalinae, Clirinae). Күпчелек ачык яшәүче личинкаларның гәүдәләренең ян-якларында тынычсызланганда сары-җирән төстәге зәһәр исле гемолимфа бүлеп чыгара торган махсус бизләр бар. Личинкалары, гадәттә, агулы һәм аларны кошлар ашамый. Мондый саклану реакциясе ачык яшәүче олы затлар өчен дә хас. Курчаклану туфракта яки үсемлекләрдә, ара-тирә сабакларда яки яфракларда бара, курчагы кабыксыз яки кузыда. Күп кенә Я. төрле культураларның корткычлары булып тора. Аеруча АКШтан Европага кертелгән *колорадо коңгызы* (Leptinotarsa decemlineata Say.) билгеле. Тополь (тирәк) һәм тал яфраклары б-н туенучы тополь кызыл канатлы яфрагашары (листоед краснокрылый тополевый) (Melasoma populi L.) һәм калканлы чөгендер коңгызы (Cassida nebulosa L.) киң таралган. Halticinae ассемьялыгыннан кечкенә гәүдәсе һәм сикерә торган арткы аяклары б-н аерылып торучы күп кенә төрләре басу һәм яшелчә культураларына зыян китерә.

*С.М.Шәфигуллина.*

**ЯФРАГАЯКЛЫ́ КЫСЛАСЫМАННА́Р** (Phyllopoda), кысласыманнар классыннан умырткасызлар отряды. Гәүдә төзелеше тибы буенча Я.к.ны 3 төркемгә бүләләр: саңагаяклылар (Anostraca), калканкыслачыклар (Notostraca), кабырчыклылар (Conchostraca). Россиядә якынча 255 төре билгеле, шуларның 50 гә якыны — саңагаяклылар, 5 се — калканкыслачыклар, 200 гә якыны — кабырчыклы кысласыманнар. Татарстан терр-ясендә яшәүче төрләрнең гөгәл саны билгеле түгел. Аеруча Branchipus stagnalis саңагаягы, язгы калканкыслачык (Lepidurus apus), җәйге калканкыслачык (Triops cancriformis), кабырчыклы кыслачыклар (Lynceus brachyurus һәм

Cyzicus tetracercus) киң таралган. Кайвакыт сирәк кенә Chirocephalus, Pristicephalus һәм Streptocephalus ыругы вәкилләре очрый. Кабырчыклыларның гәүдә озынлыгы 1–17 *мм*, калканкыслачыкларныкы — 4–5 *см*, саңагаяклыларныкы — 7 *см* га кадәр. Калканкыслачыклар сырт-корсак юнәлешендә яссыланып тора, саңагаяклылар ян-яктан кысылган, кабырчыклылар ике капкачлы хитинлашкан кабырчык эчендә; баш, күкрәк, корсак, бер пар җепсыман үсентесе булган фуркага бүленә. Башында төрле озынлыктагы һәм төрле функция үтәүче 2 пар антенна урнашкан. Алар хәрәкәт итү (кабырчыклылар), парлашу вакытында ана затны эләктерү һәм ычкындырмау өчен (саңагаяклылар) хезмәт итәләр. Күзләре утырма яки хәрәкәтчел сабакчыкларда урнашкан. Күкрәге яфраксыман аяклы 11–32 сегменттан тора (исеме шуннан). Башлыча, аталанмаган күкәйләр ярдәмендә үрчи, алар кибүне һәм туңуны җиңел кичерәләр, тереклек сәләтен 7–9 ел саклыйлар. Я.к., нигездә, вакытлыча гына хасил булган зур булмаган сулыкларда яшиләр, микроскопик суүсемнәр, суны фильтрлау юлы б-н вак органик кисәкчекләр (саңагаяклылар һәм кабырчыклылар) б-н туеналар, калканкыслачыклар ш.у. умырткасыз хайваннарга, чукмарбашларга һәм балык маймычларына һөҗүм итәләр, шул сәбәпле буа балыкчылыгына зыян китерәләр.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Определитель фауны России. СПб., 1996. Т. 2. *В.А.Яковлев.*

**ЯФРАКЛЫ́ УРМАННА́Р**, яфраклары сабакчыл пластинкалы агач токымнары берлеге; Җир шарындагы урман капламының төп компоненты. Я.у. составындагы урман барлыкка китерүче токымнарның саны ылыслы урманнарны барлыкка китерүчеләр саныннан берничә тапкыр күбрәк. Аларны киң яфраклы (каты яфраклылар) һәм вак яфраклы (йомшак яфраклылар) урманнарга аералар. Киң яфраклы урманнар яфраклары шактый киң, тыгыз һәм үзагачы каты (*имән, юкә*, бүк агачы, *корычагач, өрәңге* һ.б.), вак яфраклылар — яфраклары вак һәм үзагачы җиңел (*каен, усак, тополь, зирек* һ.б.) булган агачлардан тора. Киң яфраклы урманнар беренче үсү стадияләрендә әкрен үсүләре, кагыйдә буларак, авыр яңартылучы һәм озын гомерле агачлар б-н аерылып тора. Вак яфраклы урманнар, киресенчә, ачык урыннарда яңадан җиңел үсеп чыгалар, беренче еллардан ук тиз үсәләр, әмма озак яшәмиләр, аннары аларның урынын киң яфраклы яки ылыслы урманнар ала.

Татарстанда киң яфраклы урманнар Көнбатыш Кама алдының көньяк өлешендә, Идел алдында һәм Кама аръягында таралганнар. Имән, юкә, очлы яфраклы өрәңге, карама һәм элмә агачлары б-н формалаша. Куаклыкта чикләвек куагы, сөялле кабар агачы, гади зелпе, мурт эт шомырты, Кама аръягында дала чиясе, күгән өстенлек итә. Туфрак өслегенең тере капламы урман флорасыннан: гади сәрдә, күпьеллык зибык уты, Европа тайтоягы, язгы кырлы борчак һ.б., ш.у. эфемероидлар: Галлер сәрдәнәсе, казаяксыман җилдәк, каз юасы һ.б. үсемлекләрдән тора. Киң яфраклы урманнар — геоботаника термины. Урман хуҗалыгында Я.у.ны каты яфраклыларга һәм йомшак яфраклыларга бүлү кабул ителгән. Киң яфраклы урманнарның төп доминанты булган вак яфраклы юкәне йомшак яфраклылар төркеменә кертәләр.

Киң яфраклы токымнар арасында аеруча сабакчалы имәннең әһәмияте зур. 20 йөздә Урта Идел буе һәм Татарстан имәнлекләре 2 тапкыр: 1939–41 еллардагы кышкы каты суыклардан һәм 1978–79 дагы экстремаль түбән темп-ралы кыштан соң күпләп коруга дучар була, бу вакытта имәннәрнең коруы экологик катастрофа сыйфатын ала. Берничә ел дәвамында тамырыннан корыган имәннәрнең күләме 10 млн. $м^3$ га җитә, өлгергән, өлгереп



«Түбән Кама» милли паркы территориясендә яфраклы урман.

килүче һәм уртача яшьтәге имәнлекләр тулысы б-н корып бетәләр. Салкын тигән имәннәрнең коруы дәвам итә. Исән калган имәннәрдә салкын тию нәтиҗәсендә үзагачын күпшәкләндерүче божралар барлыкка килә, бу агачның техник сыйфатын төшерә. Салкыннардан ш.у. өрәңге, элмә, чикләвек куагы корый, өлешчә юкәгә зыян килә. 1998 гә каты яфраклы урманнарның мәйданы 1944 ел б-н чагыштырганда 313,8 мең *га* дан 182 мең *га* га кадәр (42% ка) кими. 2015 ел башына каты яфраклы урманнар мәйданы 193 мең *га* тәшкил итә.

Вак яфраклы урманнар күпчелек очракта икенчел урманнар булып тора, алар тоташ кисү, янгын, күпләп җил аудару, бөҗәкләрдән зыян күрү һ.б. нәтиҗәсендә юкка чыккан ылыслы һәм киң яфраклы урманнар урынында барлыкка киләләр. Алар өчен ачык мәйданнарда барлык уңайлы шартлар бар; еш һәм күпләп җимеш бирүе, җиңел булуы сәбәпле орлыкларның ерак араларга тарала алуы аларга урмансыз ачык урыннарны яулап алуны җиңеләйтә (ачык мәйданнарны беренчеләрдән булып яулап алулары өчен каен һәм усакны пионерлар дип йөртәләр). ТРда вак яфраклы урманнар якты, үлән капламының төрле һәм бай булуы б-н характерлана. Алар урман б-н капланган мәйданның 445 мең *га* яки 40,5% ын билиләр, шуның 238 мең *га* ы (21% тан артыгы) усакка туры килә. Вак яфраклы агачлар б-н берләттән йомшак яфраклы урманнарга юкәлекләрне дә кертәләр. Алар б-н бергә йомшак яфраклы урманнарның мәйданы 646,4 мең *га* яки урман б-н капланган мәйданның 57,5% ын тәшкил итә.

*Ә.Һ.Газизуллин.*

**Я́ХИН** Альберт Гатуф улы (8.11.1931, Арча р-ны Арча штп – 2.10.2010, Казан), әдәбият галиме, журналист, филол. фән. канд. (1964), РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1973). Казан ун-тын тәмамлый (1954). 1959 елдан «*Чаян*» ж-лында баш мөхәррир, 1975 тән Казан ун-тында (1975–81 дә татар әдәбияты каф. мөдире). Хезмәтләре Ш.Усманов иҗатына, татар фольклоры әсәрләрен һәм жанрларын системалы өйрәнүгә карый. Дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр, урта мәктәпләр өчен татар әдәбиятыннан эшләнмәләр, хикәяләр, пьесалар авторы.

Х е з м.: Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе. К., 1979 (автордаш); Система татарского фольклора. К., 1984.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**Я́ХИН** Кәүсәр Камил улы (19.1.1949, Баулы р-ны Салкын Чишмә а.), психиатр, мед. фән. д-ры (1993), проф. (1994), ТРның атказ. табибе (2000). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), шунда ук психиатрия кафедрасында эшли (бүленеп: 1974–76 елларда Яшел Үзән психоневрология диспансерында), 1997 дән психиатрия һәм наркология каф. мөдире, бер үк вакытта, 1993–2009 да, дипломнан соңгы белем бирү буенча проректор. Хезмәтләре эшчеләрнең психик сәламәтлегенә хезмәт факторлары тәэсирен бәяләүгә һәм психик тайпылышлар чиге профилактикасына карый. ТР Психиатрлар җәмгыяте рәисе (1995 тән), Россия психиатрлар җәмгыяте рәисе урынбасары (2005).

Х е з м.: Физические факторы окружающей среды и психическое здоровье. К., 2007 (автордаш); Соматические расстройства в клинической психологии. К., 2008 (автордаш); Психологическая помощь лицам с суицидальным поведением. К., 2009 (автордаш); Оценка риска развития антипсихотик-индуцированных метаболических нарушений: возможности фармакогенетического тестирования // Практическая медицина. 2017. № 2 (автордаш).

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**Я́ХИН** Мәхмүт Хажи улы (6.6.1914, Кукмара р-ны Пычак а. — 2.8.1999, шунда ук), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1962), проф. (1983). Казан финанс-икътисад ин-тын (1951), СССР Финанс халык комис-тының Бөтенсоюз финанс академиясен (Ленинград, 1955) тәмамлый. 1930 елдан туган авылында колхозда эшли. 1933–39 да Кукмара, Шөгер һәм Питрәч р-ннары башкарма ком-тларында инспектор, финанс бүлеге мөдире, Татарстан финанс халык комис-тының салымнар һәм җыемнар бүлеге өлкән инспекторы. 1940–41 дә Молдавия ССР Дәүләт контроле халык комис-ты өлкән тикшерүчесе.

1946 дан ТАССР Финанс министрлыгының идарә башлыгы, 1947–53 тә салым бүлеге башлыгы; 1955–61 дә Кыргызстан ССР Финанс министрлыгында. 1961–68 дә Кыргыз ун-тының финанс һәм кредит кафедрасында. 1962 дән каф. мөдире. 1968 дән Рига гражданнар авиациясе инженерлары ин-тын-

да (хәзер Рига авиация ин-ты), статистика һәм хисап (соңрак финанс һәм кредит) кафедрасын оештыра һәм аның мөдире була, 1977–93 тә шул кафедраның профессоры. Югары уку йортлары өчен илебездә беренче «Һава транспорты финанслары» («Финансы воздушного транспорта») дәреслеге авторы. Хезмәтләре илебезнең гражданнар авиациясе финанслары мәсьәләләренә карый. СССР Гражданнар авиациясе министрлыгы икътисади советының методологик финанс секциясе әгъзасы (1969–93). Бөек Ватан сугышы ветераны. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр; Кыргызстан һәм Латвия ССР ЮС Президиумнарының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Финансы воздушного транспорта. М., 1983. *Ф.С.Зыятдинов.*

**Я́ХИН** Рәшит Гарәфетдин улы (4.1.1960, Киров өлкәсенең Вятские Поляны р-ны Түбән Шөн а. — 17.11.2016, Казан), физик, техник фән. д-ры (2008). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1981), шунда ук эшли. 1987 елдан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында. 1996 дан ТР ФАдә, фәнни-оештыру бүлеге башлыгы (2002 дән), бер үк вакытта, Казан пед. ун-тында (2001–09) һәм Казан техник ун-тында (2009 дан). Хезмәтләре матдәләр структурасын җимермәс контрольләү өчен магнит резонансы алымнарын үстерүгә багышлана. Биол., мед., һәм археол. объектларны тикшергәндә ЭПР һәм ЭПР-томографиянең кайбер алымнарын куллану буенча экспериментлар үткәрү методикасын эшли. Икеләтә төш-электрон резонансының нәстационар алымы түбән кырлы ТМР-томографта физик-химик тикшеренүләр үткәрүдә кулланылыш таба. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХның көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Дефектоскопия на основе ЭПР-томографии // Журн. прикладной спектроскопии. 1994. Т. 61, № 3–4 (автордаш); Динамическая поляризация протонов, молекулярное движение, эффекты сольватации. К., 2002; Использование метода ЭПР томографии в дефектоскопии диэлектрических элементов высоковольтного оборудования // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2007. № 3 (автордаш).

**Я́ХИН** Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы (16.8.1921, Казан — 23.11.1993, шунда ук), композитор, пианист, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1964, 1970), РСФСРның һәм СССРның халык артисты (1981, 1986). Мәскәү консерваториясен (В.Белый һәм Ю.Шапоринда композиция классы һәм В.Эпштейнда фортепиано классы) тәмамлый (1950). Бөек Ватан сугышы башлангач, Казанга эвакуацияләнә: Татар радиосында пианист-аккомпаниатор булып эшли. 1942–45 елларда Мәскәү Хәрби округының Һава һөҗүменнән саклану гаскәрләрендә хезмәт итә; армия җыр һәм бию ансамблендә пианист-аккомпаниатор буларак чыгыш ясый, ансамбль өчен хәрби тематикага шактый җырлар яза. СССР Композиторлар берлеге әгъзасы (1948 дән даими рәвештә РСФСР һәм ТАССР Композиторлар берлекләренең идарә әгъзасы булып сайлана). 1950–52 дә Казан консерваториясендә укыта: композиция һәм камера ансамбле класслары алып бара. 1952 дән үзен тулысынча композиторлык һәм башкару эшчәнлегенә багышлый. Я. татар мелосына хас үзенчәлекләрне үзенчә шәрехли, Көнбатыш Европа һәм рус романтик композиторлары традицияләреннән уңышлы файдалана. Искиткеч аһәңле, кабатланмас көйләр тудыру остасы. Я. әсәрләре башкаручыларны һәм тыңлаучыларны гармониягә, хис-кичерешләргә бай-лыгы б-н җәлеп итә. Татар камера-вокаль һәм камера-инструменталь (нигездә, фортепиано) музыкасы үсешенә төп өлеш кертә. Композиторның романсларында һәм җырларында лирика диапазоны бик киң — якты, хыялга бай, элегик хис-кичерешләрдән алып сокландыргыч-экспрессив, драматик рух югарылыгына кадәр. Аеруча популяр әсәрләре: «Мәхәббәт җыры» (Г.Тукай шигыре), «Ышанам» (Л.Айтуганов шигыре), «Безнең әниләр», «Ак җилкән» (М.Ногман шигырьләре), «Дулкыннар» (М.Җәлил шигыре), «Китмә, сандугач» (Г.Зәйнашева шигыре), «Керим әле урманнарга» (Г.Мөхәммәтшин шигыре), «Күңелемдә яз» (Г.Насретдинов шигыре),



Р.М.Яхин.

«Шекспирның 109 нчы сонеты» («Сонет Шекспира № 109», С.Маршак тәрҗемәсе) һ.б. Аеруча фортепиано өчен язылган әсәрләрендә Я.ның индивидуальлеге тулысынча тормышка ашырыла. Аларда ул композитор һәм проф. пианист буларак ачыла. Аның «Оркестр белән фортепиано өчен концерт»ы, фортепиано пьесалары («Вальс-экспромт», «Юмореска», «Токката», «Ноктюрн» һ.б.) милли концерт һәм уку-укыту репертуарының төп һәм аеруча еш башкарыла торган әсәрләреннән санала. Я. иҗатында фәлсәфи, гражданлык, патриотик тематикага язылган әсәрләр мөһим юнәлеш ала. М.Җәлил шигырьләренә «Моабит төрмәсендә» вокаль циклы аеруча игътибарга лаек. «Туган ягым» җырына ул язган көй ТРның Дәүләт гимнына әверелә (1993). Я. — концертлар куючы беренче татар пианисты (солист, концертмейстер, ансамблист). Аның репертуарын үз әсәрләре, ш.у. Көнбатыш Европа, рус, татар композиторлары музыкасы тәшкил итә. Я. СССР, Финляндия (1968), Югославиядә (1977) зур уңыш б-н чыгышлар ясый; солист буларак Г.Столяров, Г.Рождественский, Ф.Мансуров, Н.Рахлин, В.Павлов (Болгария) һ.б. дирижёрлар б-н симф. концертларда катнаша. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1959). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Я. әсәрләре, нигездә, барлык Татарстан музыкантлары репертуарын тәшкил итә, ш.у. респ-кадан читтә зур танылу ала. Төрле елларда аның әсәрләрен А.Огнивцев, А.Ведерников, А.Днишев, Р.Джаманова, А.Кривченя, Е.Серкебаев, Г.Туфтина, Н.Поставничева кебек популяр җырчылар; З.Шаһморзаева, Х.Әхтәмова һ.б. скрипкачылар башкара. Татар опера һәм балет театрында куелган «Фидаи» балеты Я. музыкасының кызыклы шәрехләмәләреннән берсен (1987, Р.Такташ һәм Л.Исакова либреттосы) тәшкил итә. Нәшер ителгән җыентыклар (30 дан артык) һәм фортепиано концерты клавиры, Я. әсәрләренең фондта сакланган аудио- һәм видеоязмалары (300 дән артык) аның иҗат мирасына ихтыяҗ зур булуны раслый. 2003 тән Казанда Я. исем. Халыкара камера җырчылары һәм концертмейстерлар конкурсы уздырыла. Казанда Я.га һәйкәл куелган (2017), ул яшәгән йортта мемориаль такта урнаштырылган, бер урам аның исемен йөртә.



Р.М.Яхин.

Төп әсәрләре: «Урал» (К.Даян шигыре), «Идел» (Р.Харис шигыре) кантаталары; «Кояшлы яңгыр» (Р.Харис шигыре), «Яшерен сагыш» (татар шагыйрьләре шигырьләре) вокаль цикллары; Фортепиано өчен сюита, Соната; «Җәйге кичләр» фортепиано циклы; Скрипка һәм фортепиано өчен соната, «Поэма», «Сүзсез җыр» («Песня без слов»), «Борынгы көй» («Старинный напев»); виолончель һәм фортепиано өчен «Элегия»; 450 дән артык романс һәм җыр.

*Әд.:* Композиторы Советского Татарстана. К., 1957; Ш у м с к а я Н.А. Рустем Яхин. М., 1958; В и н о г р а д о в Ю.В. Рустем Яхин — композитор и пианист // Композиторы Российской Федерации. М., 1981. Вып. 1; И с а н б е т Ю.Н. Рустем Яхин // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Рустем Яхин: Материалы. Письма. Воспоминания. К., 2002; Рустем Яхин: Стиль творчества. К., 2002; Рустем Яхин в воспоминаниях современников. К., 2004; Композиторы Татарстана. М., 2009.

*Ф.Ш.Салитова.*

**Я́ХИН** Таиб (Мөхәммәдтаиб) Гыйльман улы (1845, Мамадыш өязе Байлангар а. – 1910, Казан), язучы, педагог. Кышкар мәдрәсәсендә, Казан мәдрәсәләренең берсендә укый, Оренбург мөселманнар Диния нәзарәтендә имам-хатип һәм мөдәррис дәрәҗәләренә ирешү өчен имтихан тапшыра. 1880 елда Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый, Казанда рус-татар уч-щесендә эшли, 1884–1910 да Казан татар укытучылар мәктәбендә сыйныф-дәрес системасы буенча, *җәдитчелек* принципларына нигезләнеп, мөселман дине гыйлемен укыта. «Хөласат әл-мәсаил вә мөһиммәт» («Мәсьәлә вә бурычларның

асылы», 1890), «Мөһиммәт әл-әүляд әл-мөслимин» («Мөселман балалары өчен мөһим, кыйммәтле әйбер», 1895), «Бәйрәмнәр мәгълүматы һәм яшь талибләргә нәсихәт» («Яшь шәкертләргә нәсыйхәт, яисә Бәйрәмнәр турында мәгълүмат», 1897), «Тәгълим әл-әдәб иләл вәләд» («Балаларда әдәп тәрбияләү», 1898), «Тәзкирәт әт-табигать» («Табигать турында хикәяләр», 1901) китаплары; балалар өчен «Сабый вә сабыялар өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олуглары тәнбиһ өчен гаҗәеб булган гыйбрәтләр» («Балалар өчен кызык хикәяләр һәм мәкаләләр, олылар өчен гыйбрәтле, кызыклы үгет-нәсыйхәтләр», 1897), «Дәфгыль-кәсәл мин әс-сабый вә әс-сыйбъяти, ягъни яшь ир балалардан вә һәм яшь кыз балалардан ялкаулыкны җибәрә торган хикәяләр» («Малайларның һәм кызларның ялкаулыгына каршы, яисә балаларны ялкаулыктан коткара торган хикәяләр», 1900) хрестоматияләре авторы.

*Әд.:* Гайнуллин М.Х. Татар әдәбияты. XIX йөз. К., 1968. *Ф.И.Ибраһимова.*

**Я́ХИН** Фәрит Зәкиҗан улы (2.1.1961, Сарман р-ны Дүсем а.), язучы, әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2000), проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1983), СССР Фәннәр академиясе Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1997 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты) эшли. 1993 тән Габдулла Тукай әдәби музее директоры. 1999–2011 дә Татар гуманитар пед. ун-тында татар әдәбияты каф. мөдире, 2011 дән Казан ун-тында, 2016 дан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында. Хезмәтләре татар әдәбияты тарихына, әдәбият белеменә, 20 йөз башы татар журналистикасына, текстологиягә һәм урта гасырлар авторларын тәгаенләүгә, ислам тарихына, ислам дине белеменә карый. Урта гасырлар шагыйрьләре Ә.Ясәви, С.Бакыргани, Мәҗлиси, Сәйяди, С.Аллаһияр, Әмдами һ.б. әсәрләрен текстологик яктан басмага әзерли. Я. «Август ае» (1995) роман-дилогиясе, «Пәйгамбәребез Мөхәммәд» (1997) трилогиясе, «Куш каен аланлыгы» (2009), «Умырзая» (2012) романнары; «Ак әбиләр догасы» (2000), «Сөйкемле сөяк» (2004), «Тоз тәме» (2011) хикәяләр җыентыклары авторы. Әсәрләрендә татар халкының рухи тормышын тирән белүе чагыла. Поэзиясенә дөньяга фәлсәфи караш хас: «Гүргә кадәр сакланган сөю» (1995), «Таңга кайту» (1996), «Хис керфегемдә күз яшең» (1998) шигырьләре; 1990 еллар ахырында — 2000 еллар башында тарихи шәхесләр Мөхәммәдъяр, Кол Шәриф, Шаһгали, Гали Әкрәм турында поэмалар иҗат итә.

Хезм.: Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. К., 2000; Урта гасырлар татар әдәбияты. К., 2003; Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбияты. К., 2011; Татарская литература в периодической печати Уральска (1905–1907). К., 1992.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2. *Р.Р.Мусабәкова.*

**Я́ХИН** Фидаил Шәехәбрар улы (6.7.1941, Курган өлкәсе Сафакүл а. — 5.1.1990, Томск ш.), гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы. В.И.Мухина исем. Ленинград югары сәнгать-сәнәгать уч-щесенең нәфис керәч һәм пыяла бүлеген тәмамлый (1976). 1977–90 елларда Лучаново пыяла заводында (Томск ш. янында) пыяла һәм керәч бизәүче баш рәссам була. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1983). Керәч һәм пыяла сәнгатен үстерүгә, Томскины Россия нәфис пыяла эшләнмәләре үзәгенә әверелдерүгә зур өлеш кертә. Я. ның әсәрләре (вазалар, декоратив тәлинкәләр, сервизлар сериясе, тәмле су савытлары, бокаллар һ.б.) автор стиле оригинальлеге һәм сәнгатьчә матурлык, сыгылмалылык үзенчәлекләре, бизәлеш матурлыгы б-н аерылып тора. Гута техникасында эшли, төсле һәм үтә күренмәле пыяланы файдалана, бизәкләр, гравировка, матировка, алмаз б-н кырлау куллана. Төп әсәрләре: «Обь буе чәчәкләре» (1979), «Себер елгалары» (1980), «Есенинга багышлау» (1982), «Дастархан» (1985), «Этюдлар» (1986). Шәхси күргәзмәләре 1988, 1991, 1996 (Томск), 1988 дә (Мәскәү) үткәрелә. Әсәрләре Томск өлкә сәнгать музеенда, Томск өлкә төбәкне өйрәнү музеенда саклана.

*Әд.:* Поэзия стекла: Фотоальбом. Томск, 1991; Энциклопедия Томской области. Томск, 2009. Т. 2. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**Я́ХИН Ш. ТАШБАСМАХАНӘСЕ́**, Казанда. Казандагы беренче татар китап басу йорты һәм ташбасмаханәсе. 1843 елда яки 1844 тә *Яхин Шаһи* тарафыннан Яңа Татар бистәсендә ачыла. 1844 тә 4 басма чыгарыла. 1845–50 дә ташбасмаханә эшчәнлеген туктата, чөнки татар китапларын хосусый басмаханәләрдә басу тыела. Китап басу эше торгызылгач, 1851–54 тә 6 исемдәге китап чыга, алар арасында — шәмаилләр, таблицалы календарьлар, борынгы татар һәм Шәрекъ классик әдәбияты әсәрләре. Миссионерларның цензурасы һәм әзәрлекләве хуҗасын эшеннән баш тартырга мәҗбүр итә. 1859 да ташбасмаханә Казан мещаны Мөхәммәтвәли Мозаффар улы Яхинга сатыла (Печән мәйданында, Юнысов йортында, аннары Кече Проломный урамында Суслов йортында урнаша). 1859–69 да ташбасмаханәдә 19 татар китабы, ш.и. тарихта беренче тапкыр татар китабын басу эшендә мулла һәм педагог Р.Әбдерәшитов төзегән, Р.Әмирханов тарафыннан басмага әзерләнгән геогр. карта («Җәгърәфи харита»; форматы 74×85 *см*); татар теле әлифбасы, тарихи-дини җыелмалар, догалыклар, шәмаилләр чыга. Бастыру программасы К.Насыйри катнашында әзерләнгән татар телендәге «Таң йолдызы» г-тасын нәшер итү планлаштырыла. Газетаны чыгаруга рөхсәт ала алмыйча, 1871 дә М.М.Яхин ташбасмаханәне яба, 1872 дә И.А.Абдуллинга сата. Ш.у.к. *Абдуллиннар И.А. һәм А.И. ташбасмаханәсе.*

*Әд.:* Каримуллин А.Г. У истоков татарской книги. К., 1992; Габделганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005. *Г.Г.Габделганиева.*

**Я́ХИН** Шаһи (? — 1854 кә кадәр), китап басучы, Казандагы ташбасмаханә хуҗасы. 1851–54 елларда Мисыр, Сүрия, Һиндстан, Ливан һ.б. илләрнең шәһәр һәм мәчет күренешләре б-н шәмаилләр бастырып чыгара. Я. ташбасмаханәсендә беренче басмаханә эше осталары тәрбияләнә.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга пореформенной России. К., 1983; Ключевская Е.П. Словарь Казанских художников 2-й пол. 16 — нач. 20 вв. СПб., 2009.

**ЯХШЫ́ КАРА́Н** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мәллә елгасы буенда. 2010 елда 134 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче чирегендә нигезләнә. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1922 дә төзелә; архит-ра истәлеге), мәктәп, су тегермәне, ашлык саклау-сату кибете эшли. Авыл җәмәгатенең имана җире 1152 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостенда, 1921 дән ТАССРның Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 75 ир-ат; 1834 тә — 205, 1870 тә — 298, 1906 да — 553, 1920 дә — 695, 1926 да — 528, 1938 дә — 580, 1949 да — 491, 1958 дә — 439, 1970 тә — 540, 1979 да — 424, 1989 да — 117, 2002 дә — 160 кеше.

**ЯХШЫБА́ЕВ** Сабит Габделбасыйр улы (1890, Оренбург губ., Югары Урал өязе Суер а., хәзер БРның Учалы р-ны Суяргол а. — 14.7.1930, Уфа ш.), театр рәссамы, иң беренче татар нәкышьчеләренең берсе. 1912 елда драматург Г.Камал тәкъдиме б-н Казан сынлы сәнгать мәктәбенең әзерлек бүлегенә йөри, П.Бенькова шөгыльләнә. «Сәйяр» татар труппасына, Г.*Кариев* антрепризасына эшкә чакырыла (Казан). Гражданнар сугышы елларында Я. Кызыл Армия театрлары труппаларында эшли, 1920 дән В.Мортазин-Иманский чакыруы буенча 1 нче Башкорт драма театрында. 1922 дә Х.Ямашев исем. рәсем мәктәбендә укыта, аның укучы-



Ф.Ш.Яхин. 1. «Яшел пута». Төсле пыяла. Тоныкландыру, алмаз белән эшкәртү. 1981; 2. «Мәкләр». Төсле пыяла. Бизәк төшерү, тоныкландыру. 1983; 3. «Су». Төсле пыяла. Гута техникасы, бизәк төшерү. 1986.





С.Г. Я х ш ы б а е в. 1. «Рамазан алдыннан кешелек гөнаһларыннан арыну». «Ялт-Йолт» журналыннан. 1912. №49; 2. Г.Камал портреты. 1914.

ларының берсе — танылган татар театр белгече Х.Х.Гобәйдуллин.

Татар һәм башкорт театрларының беренче рәссам-декораторы. «Сәйяр» труппасына килгәч, Г.Камалның «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре» (икесе дә — 1912), Ф.Әмирханның «Тигезсезләр» (1915) һ.б. спектакльләрнең сәнгатьчә бизәлеше режиссёрның фикерләвенә тәңгәл килә башлый. Зур театрда Н.В.Гогольнең «Ревизор», Е.Карповның «Эшчеләр бистәсе», М.Бурановның «Ашказар» (1919–22), А.М.Таһировның «Яңгура», М.Фәйзинең «Хәмдия», Х.Ибраһимовның «Мосафир мулла», Г.Хәмиднең «Һинд кызы» (1923–24) спектакльләрен бизи. Я.ның сәхнә бизәлешенә милли көнкүреш әйберләре кулланылган фронталь план өстенлек итү хас. Я.ның картиналары арасында Г.Камал, Г.Кариев, С.Гыйззәтуллина-Волжская портретлары бар (барысы да — 1914). 1920 елларда халык примитив иҗатына тартым сәнгать үрнәкләре — жанрлы композицияләр, портретлар («Авыл», «Өй», «Татар крәстияне», «Татар») иҗат итә. Казанда Шәрекъ клубында уздырылган 1 нче Татар рәссамнары күргәзмәсендә катнаша (1912).

*Әд.:* С у л т а н о в а Р.Р. Бесценный опыт первых профессионалов: Галиасгар Камал и первый художник татарского театра Сабит Яхшибаев // Казань. 2004. № 1.

*Р.Р.Солтанова.*



С.Г. Я х ш ы б а е в. «Ике мәхәллә – ике Рамазан». «Ялт-Йолт» журналыннан. 1912. №48.

**ЯХШЫБА́Й** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 23 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 71 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларда нигезләнә. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Әлки волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1922 дә — 203, 1926 да — 225, 1938 дә — 230, 1949 да — 179, 1958 дә — 175, 1970 тә — 195, 1979 да — 236, 1989 да — 82, 2002 дә — 72 кеше.

**ЯХШЫБА́Й** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 12 *км* көньяктарак, Камышлы елгасы (Минзәләнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 76 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигезләнә. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Якшибаево исеме б-н дә билгеле. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да мәчет (1907 дә төзелә; архит-ра истәлеге), мәктәп, ашлык саклау-сату һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 874 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән — Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 117 ир-ат; 1834 тә — 269, 1870 тә — 342, 1906 да — 446, 1913 тә — 557, 1920 дә — 569, 1926 да — 553, 1938 дә — 354, 1949 да — 252, 1958 дә — 219, 1970 тә — 176, 1979 да — 135, 1989 да — 95, 2002 дә — 80 кеше.

**ЯХЪЯ́** Ватанар Сәет улы (18.9.1938, Ленинград), тарихчы, географ, дәүләт эшлеклесе, тарих фән. д-ры (1975), проф. (1979), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998). Ленинград (хәзер С.-Петербург) ун-тын тәмамлый (1963). 1968 елдан Ленинград пед. ин-тында. 1979 дан Ленинград совет сәүдәсе ин-тының икътисади геогр. каф. мөдире. 1987 дән Петербург ун-тында, халыкара мөнәсәбәтләр ф-тының дөнья сәясәте каф. мөдире (1994 тән). 1991–96 да С.-Петербург мәры киңәшчесе. 1994 тән С.-Петербург Закон чыгаручы җыенының 1–5 чакырылышы депутаты, җаваплы секретаре, рәисе (2012 дән). Хезмәтләре Африка илләре тарихы, икътисади һәм сәяси географиясенә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Торговля и общественное питание в системе агропромышленного комплекса СССР: Лекция. Л., 1985 (автордаш); Природные ресурсы Африки: По странам и континентам. М., 1986 (автордаш); История Эфиопии в новое и новейшее время. М., 1989 (автордаш).

*Әд.:* Кто есть кто в Санкт-Петербурге: Биогр. ежегодник. СПб., 2005. Вып. 10.

**ЯХЪЯ́** Наил Сәет улы (17.7.1940, Ленинрад, социаль гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1975), проф. (1979). Беренче Ленинград мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Якутск шәһәрендә респ-ка хастаханәсе табибе булып эшли. 1964 елдан Якутия АССР Эчке эшләр министрлыгы мед.-сан. части башлыгы. 1967 дән Якутск ун-ты мед. ф-тының социаль гигиена һәм сәламәтлек саклауны оештыру курсы мөдире, каф. мөдире. 1980 нән Мәскәүдә, Н.А.Семашко исем. Бөтенсоюз социаль гигиена һәм сәламәтлек саклауны оештыру фәнни-тикшеренү ин-тында бүлек җитәкчесе, 1990 нан Россия мед. ун-тының (Пирогов исем. 2 нче Мәскәү мед. ин-ты) мед. тарихы һәм хокук белеме каф. мөдире. Хезмәтләре демографиянең мед. б-н бәйле мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Здоровье населения Севера. Л., 1980; Окружающая среда и здоровье населения. М., 1990.

**ЯҺҮ́ДИН** Әзәл Бәдретдин улы (14.12.1908, Казан губ., Спас өязе Яр Чаллы а. — 22.10.1997, Казан ш.), драма актёры, эстрада артисты, ТАССРның атказ. артисты (1954). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлый (1930). Сәхнә эшчәнлеген 1926 елда Спас кантонының «Зәңгәр блуза» агитбригадасында башлый. 1930–33 тә Әстерхан татар театры актёры, 1933–34 тә Әлки р-нында колхоз яшьләре театры б-н җитәкчелек итә, 1934–35 тә — Татар акад. театрында К.Шамил җитәкчелегендәге яшьләр төркеме, 1935–38 дә — Татар акад. театрының колхоз ф-лы, 1938–50 дә Татар акад. театры актёры. Бу елларда башкарган рольләре — Заһри («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Шаһбаз, Шәйхи, Шәриф («Бишбүләк», «Изге амәнәт», «Чаткылар», Т.Гыйззәт), Дәрвиш («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Хәлил («Галиябану», М.Фәйзи), Басыйр («Тормыш җыры», М.Әмир), Рәхимҗан («Якты юл», Р.Ишморат), Добчинский («Ревизор», Н.В.Гоголь), Гофмаршал («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер). 1950–68 дә Татар филармониясендә эстрада артисты, концертлар алып бара, нәфис сүз остасы.

**ЯҺҮ́ДИН** Кәрим Мусакай улы, (август 1915, Өстән Уза, хәзер Саратов өлкәсенең Петров р-ны – 20.8.1944, Литва ССР, Каунас ш.), Сов. Союзы Герое (25.10.1938), майор. Киев артиллерия уч-щесен тәмамлый (1941). 1937 елдан Кызыл Армиядә. 1938 дә Хәсән күле янындагы япон милитаристлары б-н сугышларда катнаша, 119 укчы полкның укчы батальоны (39 нчы укчы корпусның 40 нчы укчы дивизиясе) пулемётчысы. Ерак Көнчы-

гыш фронты гаскәрләре составында 1938 нең августында батырлык күрсәтә: 60 ка якын дошман солдатын һәм офицерын юк итә, үз подразделениесенең сугышчан бурычын үтәргә булышлык итә. 1942 нең мартыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, взвод, батарея, дивизион командиры. Ленин ордены, Александр Невский, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.Туган җирендә Геройга мемориаль такта куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЯҺҮ́ДИН** Мигъдәт Гобәйдулла улы (7.7.1904, Саратов губ. Яңа Әләзән а. — 1982, Ташкент), дәүләт эшлеклесе. Үзәк төрки хәрби-сәяси мәктәбен (Казан, 1927), Кызыл профессорлар ин-тын (Мәскәү, 1937) тәмамлый. 1927–29 елларда профсоюзларның Әгерже район ком-ты рәисе. 1929–32 дә ТАССР хезмәт халык комиссары. 1932–34 тә ТАССР ҮБК Президиумы рәисе, бер үк вакытта, 1932 дән, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты бюросы әгъзасы һәм секретаре. 1939–41 дә укыту комб-ты мөдире, ВКП(б) Дзержинский район ком-тының (Мәскәү) агитация һәм пропаганда бүлеге инструкторы, 1941–45 тә ВКП(б)ның Зейск-Алдан округ ком-тының агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире урынбасары, ВКП(б)ның Якутия өлкә ком-ты лекторы, 1945–47 дә ВКП(б) ҮК каршындагы Читтән торып уку югары мәктәбендә тарих укытучысы. 1947 дән Урта Азиядә, 1954–73 тә Ташкент фармакология ин-тында укыта.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**ЯҺҮ́ДИН** Шамил Хәйрулла улы (10.2.1932, Пенза өлкәсенең Никольский р-ны Усть-Инза а. — 18.5.2005, Мәскәү), балет артисты, педагог, РСФСРның халык артисты (1969). 1952 елда Мәскәү акад. хореография уч-щесен (педагог А.В.Жуков), 1976 да Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) балетмейстерлык һәм пед. бүлекләрен тәмамлый. 1952–78 дә балет солисты, 1974–99 да Зур театрда педагог-репетитор. Шактый хореографик партияләр башкара: Акробат («Кызыл мәк», Р.Глиэр), Шүрәле (шул исем. әсәр буенча, Ф.Яруллин), Ганс («Жизель», А.Адан), Ротбарт («Аккош күле», П.Чайковский), Кол («Спартак», А.Хачатурян), Виноградинка («Чиполлино», К.Хачатурян) һ.б., иң уңышлы дип табылганнары — Нурали («Бакчасарай фонтаны», Б.Асафьев), Коман («Кыпчак биюләре» — А.Бородинның «Кенәз Игорь» операсыннан хореографик күренеш, А.Бородин), Пан («Вальпургиев төне» — Ш.Гунонның «Фауст» операсыннан балет күренешләре) һ.б. Я.ның концерт репертуарында В.Соловьёв-Седойның «Тарас Бульба» балетыннан «Гопак» концерт номеры аеруча зур уңыш казана, анда артист «кеше ышанмаслык көчле һәм югары сикереш» ясый. Я. биюе тәвәккәллек, зур пластика, тышкы экспрессия б-н аерылып тора. Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале (1 нче бүләк, Бухарест, 1953), Бөтенсоюз балет артистлары конкурсы (Мәскәү, 1956) лауреаты. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә (1959).

*В.Н.Горшков.*

**ЯҺҮ́ДИНА** Сөем Гыйләҗетдин кызы (25.5.1916, Әстерхан ш. — 1.10.1991, Ташкент), селекция-орлыкчылык белгече, а.х. фән. канд. (1958), Үзбәкстан ССРның атказ. агрономы (1966). 1933 елда Чарджау (Төрекмәнстан ССР) а.х. мамык техникумын, 1940 та Ташкент а.х. ин-тын тәмамлый. 1940–76 да (бүленеп) Үзбәкстан бакчачылык, виноградчылык һәм шәраб ясау фәнни-тикшеренү ин-тында: гамәлгә кертү бүлеге (1947–52), җиләк культуралары секторы мөдире (1968–76). 1942–46 да СССР ФАнең Төрекмәнстан ф-лында, Мары өлкәсе җир бүлегендә (Төрекмәнстан ССР). 1952–55 тә Үзбәкстан ССР А.х. министрлыгының Яшелчә һәм бәрәңге идарәсендә өлкән агроном. Бакча каен җиләгенең (ш.и. «Память Шредера», «Поздняя сладкая», «Узбекистанская») һәм алтынсыман карлыганның (ш.и. «Дустлик», «Кишмишная», «Плотномясая», «Узбекистанская ранняя», «Узбекистанская сладкая», «Узбекистанская крупноплодная», «Сиюма») 15 сорты авторы. Хезмәтләре җиләк культураларының селекциясе һәм агротехникасы мәсьәләләренә карый. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының дүрт көмеш һәм өч бронза медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Смородина. Таш., 1976; Ягодные культуры. Таш., 1979; Приусадебные ягодники. Таш., 1988 (автордаш).

*Р.Ә.Әсретдинова.*

**ЯШӘ́Ү МИ́НИМУМЫ**, регионда хәзерге икътисади шартларда, беренче чиратта хәзерге җитештерү дәрәҗәсендә кешегә тиешле тормыш шартларын тудыру һәм эшче көчләр булдыруга мөмкинлек бирүче минималь акча кеременең түбәнге чиге яки минималь азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар, хезмәт күрсәтү (гамәлдәге 1 кешегә исәпләнгән) җыелмасы.

РФдә Я.м. категориясе рәсми рәвештә, 1997 елда кабул ителгән «РФдә яшәү минимумы» Федераль законына таянып, 1998 нең 1 гыйнварыннан кулланыла башлый.



К.М.Яһүдин.



Ш.Х.Яһүдин.

Я.м. минималь эш хакы, пенсия күләмен, ш.у. трансферт түләүләре (стипендия, пособие, компенсация һ.б.) күләмен билгеләгәндә нигез булып тора. Үз чиратында Я.м. «кулланучылар корзинасы»на таяна. Ул минималь азык-төлек җыелмасы (икмәк, икмәк-күмәч эшләнмәләре, бәрәңге, яшелчә, җиләк-җимеш, шикәр, кондитер эшләнмәләре, ит, сөт, йомырка, үсемлек мае, маргарин һ.б. майлар; тоз, чәй, тәмләткечләр, яңа җыелган җиләк-җимешләр; һәм азык-төлек булмаган товарлар (тышкы киемнәр, костюм-күлмәкләр, эчке кием, оек-оекбашлар, баш киемнәре, галантерея эшләнмәләре, аяк киеме, мәктәптә уку-язу товарлары, урын-җир, хуҗалык товарлары, сан.-гигиена кирәк-яраклары, дарулар); хезмәт күрсәтү (торак, үзәктән җылыту, салкын һәм кайнар су, газ, электр энергиясе, транспорт һ.б.) б-н тәэмин итү бәясенә нигезләнә.

РФдә Я.м.ның бәяләтә формасын исәпләү өчен 1999 да «Россия Федерациясе буенча тулаем кулланучылар корзинасы» Федераль законы кабул ителә. Халыкның төп социаль-демографик төркемнәре: хезмәткә яраклы яшьтәгеләр, балалар, пенсионерлар өчен кулланучылар корзинасы билгеләнә (5 ел саен кабат исәпләнә). РФ субъектлары Федераль законда билгеләнгән кулланучылар корзинасы күләмендә квартал саен Я.м. күләмен яңартып торырга тиешләр. ТРда МК квартал саен Я.м. билгели; мәгълүматлар вакытлы матбугатта басылып чыга. Аеруча

1 нче таблица

**2002, 2006, 2016 елларда ТР буенча яшәү минимумы күләме**

| Күрсәткечләр, сум/ай | 2002 | 2006 | 2016 |
|---|---|---|---|
| Жан исәбеннән, ш.и.: | 1549 | 2735 | 8077 |
| эшкә яраклылар | 1685 | 3009 | 8620 |
| пенсионерлар | 1121 | 1979 | 6612 |
| балалар | 1585 | 2713 | 8013 |

2 нче таблица

**2002, 2006, 2016 елларда ТРда акча кереме яшәү минимумыннан кимрәк булган халык саны**

| Күрсәткечләр | 2002 | 2006 | 2016 |
|---|---|---|---|
| Барлыгы, мең кеше | 889,3 | 376,0 | 290,8 |
| Барлык халык санынннан процентларда | 23,6 | 10,0 | 7,5 |

3 нче таблица

**2017 елның 3 нче кварталы мәгълүматлары буенча РФ һәм Идел буе федераль округының аерым регионнарында яшәү минимумы күләме, сум/ай**

| | Уртача жан исәбеннән | ш.и. социаль-демографик төркемнәр буенча | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Эшкә яраклылар | Пенсионерлар | Балалар |
| Россия Федерациясе | 10328 | 11160 | 8496 | 10181 |
| Татарстан Республикасы | 8669 | 9269 | 7109 | 8521 |
| Түбән Новгород өлкәсе | 9370 | 10065 | 7715 | 9717 |
| Чуаш Республикасы | 8779 | 9303 | 7134 | 8916 |
| Самара өлкәсе | 10014 | 10996 | 7910 | 9931 |
| Башкортстан Республикасы | 8611 | 9187 | 7061 | 8483 |

авыр чорларда (мәс., икътисади кризис чорында) «физиологик минимум» дип аталган күрсәткеч кулланыла, аның күләме Я.м.ннан күпкә кимрәк, халыкның һәм аерым кешенең экстремаль хәлләрдә гомерен саклау өчен генә исәпләнә.

*Әд.:* Республика Татарстан. 2004; Российский статистический ежегодник: стат. сб. М., 2005; Стат. сб., К., 2006.

*Р.К.Мәҗитова, Ф.С.Зыятдинов.*

**ЯШӘҮЧЕ́** посёлогы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 34 *км* төньяктарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 98 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1930 елларда нигезләнә. Оешкан көненнән — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1989 да — 121, 2002 дә — 111 кеше.

**Я́ШЕВКА** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кыят елгасы буенда. 2010 елда 213 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 дан Кыят атамасы б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Богородский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, җир эшкәртү, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Я.да Богородица чиркәве, земство мәктәбе (1866 да ачыла), 1 су һәм 6 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 1 казна шәраб һәм 3 кибет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1480 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Колунец волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән — Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1957 нең 30 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 186 ир-ат; 1859 да — 772, 1897 дә — 1002, 1908 дә — 1114, 1920 дә — 1198, 1926 да — 1202, 1938 дә — 991, 1949 да — 590, 1958 дә — 560, 1970 тә — 500, 1979 да — 344, 1989 да — 193, 2002 дә — 248 кеше.

**ЯШЕ́Л АШЛАМАЛА́Р**, үсемлекләр-сидератларның (башлыча кузаклыларның) туфракка күмелә торган яшел массасы. Я.а. пар җирендә (сидераль пар), урылган һәм чабылган чәчүлекләрдә, ш. у. төп культура астына чәчеп үстерелә. Алар черемә б-н чагыштырганда, микробиол. таркалуга җиңелрәк бирелә һәм тәэсире буенча органик ашламаларга тартым. Барлык тип, аеруча комлы һәм комсу туфракларда кулланыла. 2003 елда ТРда сидераль культуралар 59,6 мең *га* мәйданда, ш.и. донник 27,2 мең *га* да мәйданда чәчелә. Сидератлар туфракны органик матдәләр б-н, кузаклы культуралар чәчкәндә аны азот б-н баеталар, ш.у. туфракның агрофизик үзлекләрен, су, һава һәм җылылык режимын яхшырталар. Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан булган сидераль культуралар кыска вакытлы вегетация чорында күп яшел масса үстерүгә сәләтлелеге б-н әһәмиятле (1 *га* дан 250–300 *ц*). Я.а.ның үзенчәлеге — аларда үсемлекләр тарафыннан яхшы үзләштерелүче туклыклы матдәләрнең күп булуы. Шушы күрсәткеч буенча сидератлар (кузаклылар — чәчәк ату, әвернәчәчәклеләр җимеш барлыкка килү чорында), оптималь срокларда туфракка кертелсә, тирескә караганда ике тапкыр яхшырак. Туфракка соң кертелгәндә (тупасланган яшел масса), кертелгән елда сидератларның нәтиҗәлелеге кими, аннан соңгы нәтиҗәсе арта. Теләсә кайсы очракта Я.а. туфракның уңдырышлылыгын һәм уңышны арттырырга ярдәм итә. Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты, Бөтенроссия а.х. химияләштерү фәнни-тикшеренү һәм проектлау-технол. ин-тының Идел-Вятка ф-лы, Респ-ка химияләштерү станциясе тикшеренүләре нәтиҗәсе буенча ТР өчен иң нәтиҗәле сидераль культуралар билгеләнә: донник, май бирә торган торма, рапс. Бу культуралар вак орлыклы, аларның үрчү коэффициенты югары, бу орлыкчылыкны оештыруны күпкә җиңеләйтә. Алар салкынга, корылыкка чыдам, югары экологик үзлеккә ия, җир өстендәге массаның югары уңыш бирүен тәэмин итүгә сәләтле. Яшел масса уңышына карап, чабып алганнан соң аны бер үк вакытта ваклап һәм басуларга таратып, сабаннар б-н 14–16 *см* тирәнлектә (уңыш югары булганда) яисә ике тапкыр як-яктан тырмалап, авыр тәлинкәле БДТ-7, ГД-7 тырмалары б-н 10–12 *см* тирәнлеккә күмәләр (уңыш аз булганда). Сидератларны чабып алуны һәм күмүне июльнең беренче декадасыннан соңга калмыйча төгәллиләр.

*Әд.:* Ш а к и р о в Р.С. Земное плодородие. К., 1989; Д о в б а н К.И. Зелёное удобрение. М., 1990; Система ведения отраслей агропромышленного комплекса Республики Татарстан. К., 1992.

*А.А.Җиһаншин.*

**ЯШЕ́Л КОНВЕ́ЙЕР**, яшел терлек азыгын җитештерү һәм куллану системасы, кышкы чордан соң алар б-н өзлексез һәм тигез рәвештә терлекләрне тәэмин итү. Я.к. булдыру ихтыяҗы үсемлекләрнең үсеше сезонлы булуы, җәйге чорда аларның кибүе б-н бәйле. Я.к. оештыруда хуҗалыкта декада һәм айлар буенча барлык төр терлекләр өчен яшел терлек азыгына ихтыяҗ һәм терлек азыгы культураларын җирле табигый һәм хуҗалык шартларына карап сайлау билгеләнә. Көтүлектә йөртү сезонының 3 чорга — язгы күчеш чорына (7–10 көн), җәйге төп чорга (115–125 көн) һәм көзге күчеш чорына (30–40 көн) бүленүе исәпкә алына. Я.к. составына табигый һәм ясалма (культуралы) күпьеллык көтүлекләр, күп- һәм берьеллык үләннәр (яшел масса), тамырбүлбеазыклар, яшелчәчелек калдыклары керә. Я.к. көзге арыш чәчүлекләренең яшел массасын куллланудан башлана (уңыш 1 *га* дан 70–80 *ц* булганда). 10–15 көннән соң, көзге кыяклылар б-н көзге вика катнашмасын куллануга күчәләр; бу вакытта терлекләрнең үзләштерелә торган протеин б-н тәэмин ителүе сизелерлек яхшыра. Июньнең икенче декадасыннан Я.к.да күпьеллык үләннәрне, июль башында вика катнашмасын кулланалар. Икенче тапкыр чабып алынган күпьеллык үләннәр июльнең соңгы декадасында, августның 1 нче декадасында кулланыла. Августның 2 нче декадасында — берьеллык үләннәрнең соң өлгерешле төрләре, судан үләне һәм азык тарысы, сентябрь башында — кукуруз, аннан соң күп- һәм берьеллык үләннәр курпысы ашатыла. Я.к.ны берьеллык үләннәрнең чабылган чәчүлекләре, сентябрь ахырында терлек азыгы тарысы б-н рапс катнашмасы чәчүлекләре, октябрьдә рапс төгәлли.

Барлык чәчелгән Я.к. культуралары, кагыйдә буларак, махсуслаштырылган лагерь янындагы чәчү әйләнешендә урнаштырыла, бу терлекләрне еракка йөртмәскә, яшел массаны ташыганда транспорт чыгымнарын киметергә мөмкинлек бирә һәм шуның б-н терлекләрнең гомуми продуктлылыгын арттыруга, яшел массаның һәм терлекчелек продукциясенең үзкыйммәтен киметергә ярдәм итә.

*Әд.:* Р о г о в М.С. Зелёный конвейер. М., 1985; Рекомендации по содержанию и кормлению животных в летний период 2001 года. К., 2001; М а л и к о в М.М. Система кормопроизводства в Республике Татарстан. К., 2002.

*М.М.Маликов.*

**ЯШЕ́Л КУЛЬТУ́РАЛАР**, азык буларак яшел килеш (яңа өлгергән һәм консервланган хәлдә) кулланыла торган яшелчә үсемлекләре, яфраклар, сабаклар һәм яшь сабаклар. Я.к.га кыяклы суган, салат, шпинат, укроп, рәваҗ, кузгалак, петрушка, сельдерей, хуш исле рәйхан, кориандр керә. Я.к.ның тәм сыйфатлары яхшы, составларында витаминнар һәм кыйммәтле туклыклы матдәләр бар; тиз өлгерешлеләре: яфраклы салат — 30–45 көннән соң, шпинат — 30–40, укроп — 40, кыяклы суган — 20–35 көннән соң өлгерә. Бу күп тапкыр утыртырга һәм теплицаларда — ел дәвамында, ачык һәм җылытылган грунтта яздан көзгә кадәр Я.к. үстереп алырга мөмкинлек бирә. Я.к. туфракның уңдырышлылыгына һәм дымлылыгына таләпчән. Алар ачык грунтта тыгызландырылган (томат һәм кәбестә б-н) һәм аралаш (соңгы культуралар алдыннан — томат һәм кыяр б-н) чәчүлекләрдә үстерелергә, ябык грунтта аерым урын биләргә яисә тыгызлавыч сыйфатында кулланылырга мөмкин. Я.к. салкынга чыдам, 12–15 °С та яхшы үсәләр һәм 3–5 °С кырауларны җиңел кичерәләр, шпинат кар астында да яхшы саклана. Я.к.ның ТРда районлаштырылган сортлары: салат — «Крупнокочанный» (1974), «Верадарц» (1990); шпинат — «Жирнолистный» (1974), «Стоик» (1996); укроп — «Грибовский» (1978), «Лесногородский» (1989), «Салют» (1996), «Борей» (1997), «Кибрай» (1997); петрушка — «Урожайная» (1965), «Обыкновенная листовая» (1988), «Бриз» (1996), «Сахарная» (1996); пастернак — «Круглый» (1965), «Лучший из всех» (1996); сельдерей — «Яблочный» (1973); кузгалак — «Крупнолистный» (1996), «Бельвильский» (1996); батун-суган — «Салатный 35» (1990); шнит-суган — «Медонос» (1990).

**ЯШЕ́Л ҮЗӘ́Н**, респ-ка карамагындагы шәһәр, Яшел Үзән р-нының үзәге. ТРның төньяк-көнбатышындарак, Идел елгасының сул ярында. Мәскәү–Казан линиясендәге тимер юл төене (Яшел Үзән станциясе); Йошкар-Олага, Волжскийга тимер юл тармакла-

ры уза. Көнбатышта Казан–Түбән Новгород автомагистрале үтә. Казаннан 38 *км.* еракլыкта. Мәйданы — 37,7 *км*$^2$. 2017 елда 99235 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар 64,5%, татарлар — 32,6%) яши. Шәһәрдә «Серго исемендәге завод» ҖБ» АҖ, «А.М.Горький исем. Яшел Үзән заводы», фанера, машина төзелеше з-длары, Яшел Үзән проектлау-конструкторлык бюросы, «Эра» пр-тиесе; сөт комб-ты, икмәк комб-ты эшли. Казан техник ун-ты һәм Казан инновация ун-ты ф-ллары, механика көллияте, мед. уч-щесе, 17 гомуми белем бирү мәктәбе, музыка, 2 балалар сәнгать һәм 7 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре, сәнгать галереясы, Тарихи-мәдәни мирас музее, 35 мәктәпкәчә һәм 2 клуб учреждениесе, 10 китапханә, 7 хастаханә, 4 чиркәү, 3 мәчет. Рус һәм татар



Яшел Үзән шәһәре гербы.

телләрендә «Зелёный Дол», «Яшел Үзән» г-талары нәшер ителә. Шәһәр тирәсендә табигать — ял итү һәм туризм зонасы бар.

Я.Ү.нең тарихы Зур Парат авылыннан (хәзерге Мари Респ-касы Волжск р-ны) 1854–57 елларда Идел елгасы култыгындагы ярга күченеп килүчеләрдән башлана. 1865 тә хакимият тарафыннан рәсми танылу һәм Кабачищи исеме ала (яр буендагы үзе урнашкан «Кабачищи аланы» атамасыннан). 1890 да Казан губернасының Казан өязе Ильинский волостенда мөстәкыйль авыл хокукы ала. 1898 дә чиркәү-приход мәктәбе, 1902 дә Троица чиркәве ачыла. 1880 елларда Кабачищига якын елга култыгы (затон) елга судноларының кышлау һәм төзекләндерү урынына әверелә. 1895 тә Кабачищи затонында казна судноларына хезмәт күрсәтүче даими төзекләндерү остаханәләре булдырыла (хәзерге А.М.Горький исем. Яшел Үзән з-ды). 1897 дән рәсми документларда Паратск затоны дип атала. Бу исем Я.Ү.нең үзәге булачак остаханәле посёлокка да беркетелә. Паратск затонынының (Паратскиның) үсүенә 1898 дә Франциянең Идел-Вишерск АҖ төзи башлаган корыч кою з-ды (хәзерге Серго исем. з-д) этәргеч бирә. Сәнагать объектларыннан тыш ул хакимият һәм инженер персоналы өчен 66 торак йорт та сала. 20 йөз башында посёлокта почта-телеграф бүлеге, хастаханә, трактир, чәйханә, 3 сыраханә, казна шәраб, 7 вак-төякләр кибете эшли. Беренче бишьеллык вакытында Паратск интенсив рәвештә үсә барып, ТАССРда Казан-





Яшел Үзән шәһәре. 1. Иске шәһәр. 2. Ленин урамы.

нан кала икенче сәнәгать үзәгенә әверелә. 1928 нең 21 маенда Яшел Үзән эшчеләр посёлогы итеп үзгәртелә, 1932 нең 10 мартыннан шәһәр. Сугыш алды елларында шәһәр терр-ясенә Кабачищи һәм 19 йөздә агач эшкәртү производствосы (к. *Яшел Үзән фанера заводы*) булган Яшел Үзән тимер юл станциясе посёлогы кертелә.

Бөек Ватан сугышы елларында Я.Ү. пр-тиеләре фронтка бронекатерлар, артиллерия снарядлары, авиабомба корпуслары, пулемётлар, авиация өчен фанера, башка корал һәм кирәк-яраклар җитештерә. Сугыштан соңгы унъеллыкта оборона продукциясенең яңа төрләре б-н бергә шәһәрнең «визит карточкасы» булган (су асты канатлы тиз йөрешле «Метеор» судносы, елга буксирлары, «Мир» һәм «Свияга» суыткычлары, суыткыч камералар, мебель һ.б.) әйберләр эшләп чыгару җайга салына. 1958 нең 16 августыннан Я.Ү. — Яшел Үзән р-ны үзәге. 1960–80 елларда шәһәрнең инфраструктурасы интенсив үсә: яңа торак йортлар, халык мәгарифе учреждениеләре, сәламәтлек саклау һәм мәдәният объектлары барлыкка килә. Бу чорда «Россия» кинотеатры (1962), универмаг (1969), Горький исем. мәдәният йорты (1971), автовокзал (1976), ябулы базар (1977), тимер юл вокзалы (1979), мәчет (1981), «Идел» профилакторие (1988) һ.б. эре объектлар сафка баса. Шәһәрне тәртипкә китерү, яшелләндерү, ял итү зоналары булдыруга җитди игътибар бирелә. 1990 елларда Я.Ү.дә гражданнар өчен продукциянең яңа төрләрен җитештерү башлана (5 мең *т* су сыешлы «елга — диңгез» суднолары, су асты канатлы һәм һава каверналы яңа төр пассажир суднолары, «ПОЗИС» маркалы суыткыч техника, микродулкынлы мичләр, роторлы линияләр, изотермиклы кузовлар, көнкүреш җылыту газ аппаратлары һ.б.). 1997 дән Я.Ү. — Кронштад шәһәренең тугандашы. 1991 нең 2 августыннан үз вакытында тимер юл станциясенә, соңыннан шәһәргә исем биргән *Гари* (элекке Яшел Үзән) авылы шәһәр составына керә. Халык саны: 1926 да — 3016, 1939 да — 30, 2 мең, 1959 да — 60,5, 1970 тә — 78, 1979 да — 84,9, 1989 да — 94,1, 2002 дә — 100, 1, 2003 тә — 100,3, 2010 да 97,7 мең кеше.

*Әд.:* Зеленодольску полвека. К., 1982; Город мой любимый: 70-летию города посвящается. Зеленодольск, 2002; Город, где исполняются мечты // Татарстан. 2017. № 9.

**ЯШЕ́Л ҮЗӘ́Н ЗАВОДЫ́** А.М.Горький исемендә. 1895 елда Аралашу юллары министрлыгы Казан округының Паратск суднолар ремонтлау остаханәләре буларак нигезләнә. Окт. рев-циясенә кадәр механика, казаннар, тимерчелек, кою һәм столярлык цехлары төзелә, аларда 86 кеше эшли (1907). Паратскига Балтика һәм Ижора з-длары производстволарының бер өлеше эвакуацияләнгәннән соң (1917), остаханәләр Диңгез комис-тының Идел автономияле суднолар тө-

Яшел Үзән шәһәре. Гомуми күренеше.











А.М.Горький исемендәге Яшел Үзән заводы. 1. Һава мендәрендәге «Самум» ракеталы корабле; 2. «Татарстан» океан транспорт рефрижераторы; 3. Һава кавернасындагы «Линда» елга теплоходы; 4. Тиз йөрешле «Метеор-2000» пассажир теплоходы.

зү һәм механика з-ды итеп үзгәртелә (1918). Гражданнар сугышы чорында анда *Идел буе хәрби флотилиясе* корабльләрен ремонтлау һәм яңартып җиһазлау базасы оештырыла. 1922 дә яңа исем ала — «Кызыл металлист» дип атала; суднолар ремонтлау б-н шөгыльләнә, а.х. техникасы (җилгәргечләр, ашлык сугу машиналары, тегермән ташлары), чуеннан коеп ясалган әйберләр эшләп чыгара. 1925–26 да реконструкцияләнгәннән соң халык хуҗалыгында файдаланулы суднолар (коры йөк баржалары, тәгәрмәчле буксирлар), 1934 тән хәрби кораблъләр (бронекатерлар) төзү башлана. 1932 дә заводка А.М.Горький исеме бирелә. Бөек Ватан сугышы елларында, Киевтан һәм Ленинградтан эвакуацияләнгән белгечләрне һәм җиһазларны кабул итеп, завод хәрби катерлар, ш.у. снарядлар, авиабомбалар корпуслары, зенит кораллары, пар машиналары, аэрочана детальләре, сапёр көрәкләре җитештерә. Бөтенсоюз соц. ярышында җиңүе һәм хәрби техника, сугыш кирәк-яраклары чыгарудагы уңышлары өчен Дәүләт Оборона Ком-тының Кызыл Байрагы б-н бүләкләнә (1943). 1936 да — 340 нчы завод, 1950 дә 4 нче п/я пр-тие итеп үзгәртелә. 1967 дән — Яшел Үзән суднолар төзү з-ды.

Сугыштан соңгы елларда заводта су асты көймәләренә каршы торучы кораблъләр, океанда йөзүче балыкчылык һәм транспорт рефрижераторлары, «елга-диңгез» классы танкерлары, «Звук» тибындагы ярдәмче флот суднолары төзү үзләштерелә. 1949 да СССРда беренче тапкыр җитештерү куәтләрен кискен арттыру һәм ел саен 25–35 корабль төзү мөмкинлеген биргән агымлы-позицион алымны үзләштерү башлана. 1950 дә якорьларның коелма чылбырларын җитештерүнең яңа прогрессив технологиясе гамәлгә кертелә. Пр-тие 1200 *т* га кадәр авырлыктагы судноларны суга төшерүне тәэмин иткән механикалаштырылган җайланма б-н җиһазландырыла (1957). 1967 дә Европадагы иң эре титан кою цехы, 1976 да «Идел» («Волга») суднолар төзү комплексы (составында 2 стапель цехы һәм туңмый торган док-камера) файдалануга тапшырыла, нәтиҗәдә, принципиаль яңа технол. буенча — башта 400 *т* га кадәр авырлыктагы эреләтелгән блокларны җыеп — 7 мең *т* га кадәр суыкышлы суднолар төзи башлау һәм ел әйләнәсе швартов сынаулары уздыру мөмкинлеге тудырыла.

1999 да завод «А.М.Горький исем. Яшел Үзән заводы» ДУП, 2003 нең маенда шул ук исемдәге АҖ итеп үзгәртелә. Эшләүчеләр саны — 5,1 мең кеше (2017).

Заводның суднолар төзү производствосы составында — корпус эшкәртү, җыю-эретеп ябыштыру, стапель (корыч суднолар һәм җиңел эретмәләрдән эшләнгән суднолар өчен аерым), торбалар-бакыр эшләре, маляр-изоляция цехлары, электр-монтаж участогы. Машиналар төзү производствосына корыч кою, төсле металлар һәм титан кою, тимерчелек, 3 механика цехлары, термик, гальваника участоклары керә. Ярдәмче производство заводны энергетика һәм техник ресурслар, җир өсте һәм су транспорты б-н тәэмин итүче цехларны үз эченә ала. 2011 дән җитештерүне техник яктан яңартып җиһазлау, хезмәтне оештыруның һәм идарәнең югары нәтиҗәле алымнарын куллану программасы гамәлгә ашырыла.

Пр-тие прогрессив технол. җиһазлар б-н коралландырылган; алар арасында: 1250 *т* га кадәр көчәнешле универсаль пресслар, эшләнмәләрне югары ешлыктагы токлар б-н кыздыручы торбалар бөгү станоклары, җыю-эретеп ябыштыру линияләре, 12 *м* озынлыктагы ишүче валларны һәм 1,5 *м* га кадәр диаметрлы ишүче винтларны эшкәртү өчен санлы программалы идарәле токарь станоклары, плазма кисүче машиналар, югары ныклыктагы, теләсә нинди калынлыктагы корыч, титан, алюминий-магний, бакыр-никель эретмәләре б-н эшләү өчен стенд җиһазлар. Титан кою цехында 0,1 *кг* нан 3000 *кг* га кадәр массалы эшләнмәләр коюга мөмкинлек биргән 10 вакуумлы мич (арадан берсе — Россиядә иң зурысы) һәм түгәл кою аппаратлары урнаштырылган. Сыйфат сынау стендларында, җимермәс контроль лабораторияләрендә тикшерелә. Корпус эшләү (корпус эшкәртү) һәм металлургия производстволары модернизацияләнә, дөньяның әйдәп баручы җитештерүчеләре тарафыннан чыгарылган югары дәрәҗәдә җитештерүче җиһазлар файдаланууга кертелә.

Завод илдә беренчеләрдән булып суда тотуның динамика принципларына нигезләнгән тиз йөрешле суднолар төзүгә керешә. 1961 дән тиз йөрешле су асты канатлы «Метеор» (барлыгы 300 дән артык бирәмлек), 1975–77 дә «Сокол» пасс. теплоходлары, 1980–90 елларда дөньяда беренче тапкыр су асты көймәләренә каршы торучы су асты канатлы корабль һәм һава мендәрендәге ракеталы корабль эшләп чыгарыла. 1990 елларда һава куышлыклы «Линда» елга теплоходларын, күп максатлы, тизлекле «Терьер» катерларын һәм «Метеор-2000» судноларын төзү үзләштерелә.

2002 дә — Каспий хәрби флотилиясенең флагманына әверелгән «Татарстан» сак корабле, 2012 дә — әлеге проекттагы икенче судно — РФ Хәрби Диңгез флотында «НК» универсаль ракета комплексы б-н коралландырылган беренче «Дагестан» корабле.

2000 елларда завод тарафыннан гамәлгә ашырылган проектлар арасында А-145, А-217. 1 проектларындагы тиз йөрешле пасс. теплоходлары, RST 25 проектындагы нефть ташу танкерлары һ.б. (ш.и. Әзәрбайҗан өчен), диверсияләргә каршы файдаланулы «Грачонок» катерлары серияләре, 21631 проектындагы кече ракеталы кораблъләр, «Свияга» транспорт йөзмә докы Вьетнам Хәрби Диңгез флоты өчен «Гепард-3.9» проектындагы фрегатлар төзелү һ.б. аерым әһәмияткә ия. Завод ш.у. заказчы документлары буенча кораблъләрне ремонтлау, модернизацияләү, реконструкцияләү эшләрен башкара.

Төрле елларда завод Европа илләре, Кытай, Төньяк Корея, Вьетнам, Куба, Мисыр, Сүрия, Алжир, Иран, Гыйрак һ.б. өчен суднолар төзи. Эшләү дәверендә завод тарафыннан 1,5 меңнән артык диңгез һәм елга суднолары, ш.и. 600 ләп хәрби кораблъләр төзелә.

Пр-тие продукциясе арасында — шпильләр, рульләр, чыгырлар, ишүче валлар, якорьлар, винтлар һ.б. судно җайланмалары. Нефть-газ чыгару сәнәгате өчен бораулау һәм кысып тотуры җиһазлары, агрессив мохиттә файдаланулы титан һәм корыч коелмалар (ш.у. Көнбатыш Европага, АКШка, Австралиягә җибәреләләр, Норвегиядә диңгездәге нефть вышкаларында кулланылалар)

житештерү оештырыла. 1997 дән Россиядә беренче тапкыр эре блоклы күпер металл конструкцияләрен эшләү үзләштерелә, алар Кама һәм Вятка елгалары аша күперләр төзүдә, «Миллениум» күпере, халыкара «Казан» аэропортында «Аэроэкспресс» терминалының тимер юллы эстакадасы төзелешендә һ.б.да файдаланылалар. Титаннан коелган эшләнмәләр Көнбатыш Европага, АКШка, Австралиягә җибәрелә, алар Норвегиянең диңгездәге нефть вышкаларында кулланылалар.

Завод — шәһәр һәм бюджет формалаштыручы пр-тие, тораклар, спортка нисбәтле һәм социаль-мәдәни объектлар төзелеше заказчысы. Торак йортлар, ш.и. заманча «Кызыл металлист» торак комплексы, балалар учреждениеләре, «Авангард» спорт комплексы, «Дельфин» шифаханә-профилакторие һ.б. төзелә.

Пр-тиенең халыкара дәрәҗәдә һәм Россия күләмендә танылуы «Россия икътисади лидеры» сертификаты (1995), Европа «Веритас» классификация җәмгыяте аттестаты (1997), халыкара күргәзмәләр (Түбән Новгород, 1994, 1995, 1996; Уфа, 1999; Казан, 2000, 2001), Бөтенроссия «Россиянең XXI йөздәге иң яхшы 100 машина төзү предприятиеләре һәм оешмалары» конкурсы (2001, 2010, 2015, 2017) дипломнары б-н раслана. Завод Бөтенроссия «2010 елның иң яхшы экспортлаучысы» конкурсының «Суднолар төзелеше» номинациясендә җиңә, 2013 тә сыйфат өчен РТ Хөкүмәте бүләгенә, 2015 тә РФ Президентының «Оборона сәнәгате комплексы үсешенә керткән зур өлеше һәм югары житештерү күрсәткечләре өчен» рәхмәтенә лаек була. Кече «Углич» ракеталы корабле (*Яшел Үзән проектлаштыру-конструкторлык бюросы* проекты) халыкара «Каспий диңгезе — 2015» конкурсында иң яхшы хәрби судно дип танылa. Завод Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. Күп кенә хезмәткәрләре хөкүмәт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1 кешегә — Сов. Союзы Герое, 1 кешегә — Соц. Хезмәт Герое, 1 кешегә — Татарстанның Соц. Төзелеш Герое, 10 кешегә — СССР Дәүләт бүләге лауреаты, 1 кешегә — Ленин комсомолы бүләге лауреаты, 53 кешегә — РСФСР, РФ, ТРның атказ. машина төзүчесе, 1 кешегә — РФнең атказ. технологы, 1 кешегә — РФнең атказ. химигы, 1 кешегә — РСФСРның атказ. икътисадчысы, 1 кешегә — ТРның атказ. торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре, 2 кешегә ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре исемнәре бирелә; 61 кеше — Ленин ордены, 10 кеше — Октябрь Революциясе, 175 кеше — Кызыл Байрак, 88 кеше — «Почёт билгесе», 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 42 кеше — төрле дәрәҗә «Хезмәт даны», 5 кеше — Почёт, 1 кеше — Дуслык орденнары, 14 кеше — төрле дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медальләре б-н бүләкләнә. Завод җитәкчеләре арасында — И.И.Гаврилов (1921–24), К.С.Ляховский (1924–27), С.А.Бахорин (1927–30), Ф.А.Приставко (1931–34), Ю.И.*Неометов* (1934–36), А.Ф.Майоров (1939–41), Е.В.*Товстых* (1941–45), Б.Е.*Бутома* (1945–48), В.Ф.*Ивочкин* (1948–49), А.М.Михайлов (1950–55), Г.Ф. Солдак (1955–62), Н.Д.Маркотенко (1962–66), В.И.Смыслов (1966–69), И.И.Немченко (1969–78), Л.Я.*Змачинский* (1978–84), Г.Г.Серебренников (1985–95), Е.М.Виноградов (1995–96), Г.И.Алексеев (1996–2003), С.В.Ильин (2004–09), Р.И.Мистахов (2009–2018), А.Н.Карпов (2018 дән).

*Әд.:* Корсаков Г.В. Город-сад на Волге. К.,1966; Зеленодольску полвека. К.,1982; Егорова Н.Б. Патриарх судостроения // Казань. 1997. № 7; Большому кораблю — большое плавание. Зеленодольск, 2010.

*Н.Б.Егорова, С.Г.Белов, Г.Я.Мәүлетова.*

**ЯШЕ́Л ҮЗӘ́Н МЕДИЦИ́НА УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1963 елда ачыла. Урта буын мед. хезмәткәрләрен әзерли; белгечлекләр: дәвалау эше (нигез һәм югары дәрәҗәләр), шәфкать туташы эше (нигез дәрәҗә). Урта буын мед. хезмәткәрләре өчен квалификация күтәрү бүлеге эшли. Укытучылар коллективында 34 кеше; 419 студент укый. Барлыгы уч-ще тарафыннан 6 меңнән артык белгеч әзерләнгән (шәфкать туташлары, фельдшерлар, теш техниклары). Уч-щенең 24 кабинеты булган уку корпусы, актлар һәм спорт заллары, китапханәсе, тулай торагы, чаңгы базасы бар.

**ЯШЕ́Л ҮЗӘ́Н МЕХА́НИКА КӨЛЛИЯТЕ́**, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының урта махсус уку йорты. 1939 елның мартында Яшел Үзән механика техникумы буларак ачыла, 1946–57 дә Яшел Үзән а.х. машиналары төзелеше техникумы, 1992 дән хәзерге исемдә. Белгечлекләр: логистикада операцион эшчәнлек, мехатроника һәм мобиль робот техникасы (тармаклар буенча), компьютер системаларында программалаштыру, автотранспортны ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү. Укытучылар коллективында 66 кеше, ш.и. 2 ТРның атказ. мәктәп укытучысы, 3 РФнең урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре, 1 РФнең башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре, 2 фән. кандидаты. 2018 дә 1027 студент укый. Барлыгы 14 меңнән артык белгеч әзерләнгән. Көллиятне тәмамлаучылар арасында — «А.М.Горький исем. Яшел Үзән з-ды» ДУП ген. директоры Г.И.Алексеев, «Серго исем. завод» ДУП ген. директоры А.И.Горшков. 2000 дән көллият каршында Казан техник ун-ты ф-лы эшли.

**ЯШЕ́Л ҮЗӘ́Н ПРОЕ́КТЛАШТЫРУ-КОНСТРУ́КТОРЛЫК БЮРОСЫ́**, корабльләр проектлау өчен А.М.Горький исем. *Яшел Үзән заводы* (Яшел Үзән суднолар төзү заводы (ЯҮСТЗ) каршында Үзәк КБ-340 буларак оештырыла (башлыгы — баш конструктор А.В.Кунахович), 1966 елдан хәзерге исемдә; 2000 дән ДУП. Төп конструкторлык бүлекләре: проектлау, корпуслар, механика, электр техникасы, үлчәүләр һәм материаллар; нәшрият, мәгълүмат, контроль, план-җитештерү һ.б. ярдәмче бүлекләре; Фәнни-техник совет; ЯҮСТЗнда корабльләр төзүгә техник хезмәт хезмәт күрсәтүне тәэмин итүче җитештерү бүлеге; корабль модельләрен (радио аша идарә ителүчеләрдән башлап үзйөрешлеләргә, берничә тонна сусыйдырышлыларга кадәр) эшләп чыгару, сынау, аларның гидродинамик сыйфатларын камилләштерү б-н шөгыльләнүче экспериментль бүлек булдырыла. Бөтен модельләр ачык сулыкларда сынала, соңрак (1961 дә) яңа бюро бинасында сынаулар үткәрү өчен бассейн эксплуатациягә тапшырыла.

1958 дә 201, 201 М, 201 Т, 204 проектлары корабльләре төзүгә техник яктан хезмәт күрсәтүче төп филиал Керчь шәһәрендә, 1961 дә 159, 15 А һәм 35 проектлары корабльләренә техник хезмәт күрсәтү һәм аларны эксплуатациягә тапшыру ф-лы Калининград шәһәрендә (1968 дә корабльләрне серияләп җитештерү җайга салынганнан соң ябыла) эшлиләр. Бюроның Керчьтәге ф-лы (1991 гә кадәр эшли) 1963 тән Диңгез сынау станциясе дип атала башлый. Анда 150 тонналы «Смерч» (1121М проекты) «канатлы» корабль макеты, 100 тонналы КВП-11 һава мендәрле кораб моделе, 50 тонналы «Циклон» аэродинамик бушанулы катер һәм күп кенә үзйөрешле модель һәм җайланмалар сынау үтә.










Яшел Үзән проектлаштыру-конструкторлык бюросы. 1. Су асты көймәләренә каршы торучы кече корабль (204 проекты). 1962; 2. «Альбатрос» тибындагы (1124 М проекты), су асты көймәләренә каршы торучы кече корабль. 1982; 3. «Неустрашимый» сак корабле (11540 проекты). 1992.

ЯҮСТЗнда СССР ның берничә заводында төзелә торган 201, 201 М, 357, 159, 204 һәм 35 проектлары эшләнә. Илебездә беренче тапкыр 159 проектлы корабльләрендә мотор урынына зур куәтле газ турбиналары (Николаев шәһәрендәге «Машпроект» махсус КБнда эшләнә), титан эретмәсенең юка сүрүләреннән ясалган гидроакустик антеннаның кильдәсты ягалап агызгычы кулланыла. Алга таба бу проектның (159АЭ проекты) модификацияләнгән корабльләре чит илләргә сатыла башлый. Мәскәү «Винт» КБ б-н бергә 204 һәм 35 проектлары корабльләрендә кулланылган яңа тип йөрткеч (гидромотор) эшләнә. 1965 елда 204 проекты корабль төзегәннәре өчен бюро белгечләре А.В.Кунахович, В.И.Цюпак, М.М.Гольдберг, Н.Д.Бочков һәм С.Г.Вялковка Ленин бүләге бирелә.

1963 тә бюро составында машиналар төзү махсус КБ (СКБ-М) оештырыла, аның алдына җиңел һәм кече габаритлы махсус судно җайланмалары һәм суднолар төзү тармагы өчен ясалмалар проектлау бурычы куела. Я.Ү.п.-к.б.нда су асты көймәләрен су өсте корабльләре тарафыннан сикерешле эзләнү тактикасы алга сөрелә һәм теоретик яктан нигезләнә; бу бурыч 100–200 метр тирәнлектәге суга гидроакустик станция антенналарын батыру ярдәмендә үтәлә. Буксирланучы гидроакустик антенналарны файдалану техникасы эшләнә, аның өчен СКБ-Мда чыгырлар, күтәргеч-төшергеч, ш.у. буксирлаучы җайланмалар (ПОУ һәм ПОБУ) эшләнә. 1960 елларның ахырында ПОУ беренче буларак 1124 проектлы «Альбатрос» корабленә куела. Моны башкарганнары өчен Ю.А.Никольский, Л.Ф.Федосеев, һәм Б.И.Коваленко СССР Дәүләт бүләгенә лаек булалар (1979). Су асты көймәләренең сикерешле эзләү тактикасы «Александр Кунахович» су асты канатлы корабдлен (1141 проекты, «Сокол») төзегәндә алга таба үстерелә. Ул Я.Ү.с.т.з.нда төзелеп, 1977 дә файдалануга тапшырыла. Бу тип серияле корабльләр (11451 проекты) Феодосиядәге «Море» з-дында төзелә. Алар 20 йөздә төзелгән иң зур су асты көймәсе (баш конструктор — Е.И.Овсиенко) санала. ЯҮСТЗ танклар өчен асылма йөзү җайланмаларын, «Татарстан» транспорт рефрижераторын (1351 проекты), ракета кораблен (11661 проекты, «Татарстан»), Хәрби диңгез флоты өчен «Звук» тибындагы ярдәмче (үлчәүче) судноларны (1806 һәм 18061 проектлары), «Ягуар» тибындагы экспорт судноларын (1159, 115Т, 1159ТР проектлары), чик буе елга корабльләре (1248, 1249 проектлары) проектлауны башкара, ш.у. елга кораблары сериясен (1208 проекты) төзүгә техник хезмәт күрсәтүдә катнаша, ГДР, Һиндстан, Польша, Югославия, Румыния өчен хәрби корабларны проектлау эшенә булышлык итә. Елга корабльләре комплексы төзегәннәре өчен А.А.Габсаттаров, К.Г.Коротаев һәм С.В.Русскин СССР Дәүләт бүләгенә лаек булалар (1985). 1992 дә «Неустрашимый» сакчы корабы (11540 проекты, баш конструкторы Н.А.Яковлевский) файдалануга тапшырыла.

Я.Ү.п.к.б. 20 дән артык проект эшләп чыгара, алар буенча 800 тирәсе корабль һәм судно төзелә, шуларның 150 дән артыгы чит илләргә сатыла.

1990 еллар уртасыннан бюро кече объектлар: «Терьер» катеры (14170 проекты), чик буе елга корабле (12130 проекты) төзи башлый. Конверсия тәртибендә бюро күп кенә техник проектлар башкара: гидродинамикасы хәрби кораблар өчен ясалган үзйөрешле модельләрдә сыналган автоматик рәвештә идарә ителүче су асты канатлы «Изумруд» диңгез пасс. судносы (14250 проекты); елга һәм диңгез шартларында кулланылучы «Итиль» танкеры (15230 проекты), ш.у. елга һәм диңгез пасс. һәм махсус суднолар һәм диңгездә йөрергә җайлаштырылган үзенчәлекле тримаран архит-ралы суднолар проектларын эшли.

Я.Ү.п.-к.б. нефть-газ сәнәгате һәм халык хуҗалыгы продукциясе җитештерү өчен кирәкле җиһазлар проектлый. ГПА-15 газ кудыргыч агрегатын электр б-н тәэмин итү блогы һәм скважина җиһазларын ремонтлау җайланмасының гидройөрткечле чыгыры өчен документация эшләнә; скважина җиһазларына ябышып калган асфальт-парафинны юып төшерү өчен «Волна» тибындагы активатор юдыргыч моделе ясала, аны сериялəп җитештерү Чистай суднолар ремонтлау з-дында башлана; кулланучылар өчен 4 *МВт* куәтле газ турбиналы җайланма, магистраль газ үткәргеченең ябылган бүлемтегеннән газ суырту өчен мобиль компрессор станциясе, гидравлик чыгырлы үзйөрешле каротаж күтәрткеч техник проектлары булдырыла; агач эшкәртү һәм әрҗә җыю станоклары, ш.у. төрле медицина җиһазлары модельләре ясала.

1960 еллар ахырыннан корабль, аның төзү теориясе, гидродинамикасы, ныклыгына кагылышлы исәпләүләр өчен аналог, соңыннан цифрлы ЭВМ файдаланыла. 1985 тә ЕС-1045–1 ЭВМлы Хисаплау үзәге сафка бастырыла. 1998 дән бюро персональ ЭВМ базасында хисаплау техникасы һәм ярдәмче җиһазлар б-н тәэмин ителә; локаль хисаплау челтәре булдырыла.

Бюро хезмәткәрләре мактаулы исемнәргә лаек була, СССР һәм РФнең орденнары һәм медальләре б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Полвека в кораблестроении (к производственной деятельности Зеленодольского проектно-конструкторского бюро). К., 1999.

*Г.С.Дмитриев, Р.Г.Усманов.*

**ЯШЕ́Л ҮЗӘ́Н РАЙОНЫ́**, ТРның төньяк-көнбатышында, Чуаш һәм Мари Респ-лары б-н чиктәш урнашкан. Мәйданы — 1402 *км*². 3 шәһәр, 21 авыл җирлеген, 106 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Яшел Үзән шәһәре. Халкы — 165283 кеше (2017) (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 47,7%, руслар — 47,5%). Шәһәр халкы — 25,1 мең кеше, авылларда 37,1 мең кеше яши. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1*км*²га 44 кеше. 1938 нең 4 августында Юдино р-ны буларак оештырыла, үзәге шәһәр тибындагы Юдино посёлогы була. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Казан өязенә, 1920–27 дә ТАССРның Арча кантонына, 1927–38 дә Казан авыл р-нына һәм Дөбъяз р-нына керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 953 *км*², халкы — 62,5 мең кеше, 24 авыл советы, 120 торак пункт исәпләнә. 1958 нең 16 июлендә район үзәге Юдинодан Зеленодольск шәһәренә күчерелгәч, исеме Зеленодольск (Яшел Үзән) р-ны дип үзгәртелә. 1960 та район 709,2 *км*² җир били, анда 2 посёлок һәм 10 авыл советы, 71 торак пункты исәпләнә. 1963 нең 1 февралендә ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, Я.Ү.р.на Югары Ослан, Дөбъяз, Норлат р-ннары, Биектау р-ның бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 3957 *км*², халык саны — 135,3 мең кеше, 58 авыл советы, 337 торак пункты исәпләнә. 1965 нең 12 гыйнварында респ-када адм.-терр. бүленеш үзгәрү сәбәпле, Я.Ү.р.ның мәйданы — 1475 *км*², халык саны — 71,5 мең кеше, терр-ясендә 22 авыл советы, 122 торак пункты була. Шул ук вакытта район составында элеккеге *Норлат районы* да кала.




Я.Ү.р. Иделнең ике як ярына урнашкан. Уңъяк ярдагы җир өсте — елга үзәннәре, чокырлар һәм сызалар б-н бүлгәләнгән калкулыклы тигезлектән (биеклеге 70 — 100 *м*), сулъяк ярдагы өлеше Идел тавы киртләчләреннән, сөзәк тигезлекләрдән (биеклеге 60 — 150 *м*) гыйбарәт. Район терр-ясеннән Идел (Куйбышев сусаклагычы), Зөя һәм аның кушылдыклары: Гөбенә, Әрә, Буа елгалары ага. Уңъяк ярдагы җирләр селтесез, көлсу кара-соры һәм аксыл-соры урман туфраклы; сулъяк ярдагы җирләрнең күп өлеше кәсле-көлсу туфраклы. Терр-ясенең 25% ы — урманлык. Известьташ, доломит, ком, вак таш, балчык, торф ятмалары бар. Саклаулы табигать объектлары: *Идел-Кама саклаулыгының* Раифа участогы, *«Аккул»*, *Сал күле*, *Рус-Мари Кавалы күле*, *Саба-*

*кай куле*; *Ильинка сызасы* ландшафтлы табигать истәлеге; «*Никольский*», «*Фәхри яры*», «*Кишәнгер*» ерым-сызалар системалары. Район терр-ясендә, бигрәк тә Иделнең сул ярында, энеолит, бронза гасыр, Имәнкискә культурасы, Болгар һәм Алтын Урда чорына караган 100 дән артык археол. истәлекләр табыла (к. *Карашәм хәзинәсе*). А.х. җирләре — 72,0 мең *га*, сөрүлекләр — 52,1 мең *га* (2018). Сабан бодае, көзге бодай, арыш, арпа, солы игелә; бәрәңге, яшелчә үстерелә. Терлекчелек, кошчылык, умартачылык, бакчачылык тармаклары алга киткән. 2016 да районда 13 а.х. товарлары җитештерү пр-тиесе эшли. Сәнәгать пр-тиеләре күбесенчә Яшел Үзән шәһәрендә урнашкан, моннан тыш Васильевода пыяла һәм икмәк з-длары, урман хуҗалыгы эшли. Я.Ү.р.ннан Мәскәү–Казан, Ульянов–Зөя, Яшел Үзән–Йошкар-Ола, Яшел Үзән–Волжск тимер юллары, Казан–Түбән Новгород автомобиль юлы уза. Тимер юл (Яшел Үзән шәһәре янында) һәм автомобиль (Займище посёлогы янында) күперләре, Идел аша машиналар паромы, Яшел Үзән һәм Васильево пристаньнары бар. Районда 31 гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. 2 башлангыч, 5 мәктәп-балалар бакчасы, 9 тулы булмаган урта, 15 урта мәктәп; 5 лицей, 4 гимназия, 1 прогимназия, кадет мәктәп-интернаты, 2 кичке мәктәп; 4 музыка, 2 рәсем һәм 2 сәнгать мәктәбе; 52 мәктәпкәчә яшьтәгеләр учреждениесе, 38 клуб, 4 музей, 50 китапханә, 3 хастаханә эшли. Район терр-ясендә «*Васильево*», «*Обсерватория*», туберкулёз б-н авыручылар санаторийлары, *Астрономия обсерваториясе, Богородица пустыне*, Зөя архит-ра-сәнгать музее урнашкан. Татар һәм рус телләрендә «Яшел Үзән», «Зеленодольская правда» район г-талары нәшер ителә.

**ЯШЕ́Л ҮЗӘ́Н СУДНОЛА́Р ТӨЗҮ́ ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының урта махсус уку йорты. 1944 елның маенда эвакуацияләнгән Киев суднолар төзү техникумы җирлегендә ачыла. Белгечлекләр: автоматлаштырылган мәгълүмат эшкәртү системасы һәм идарә итү, коммерция һәм реклама, кара һәм төсле металларны кою, хокук белеме, суднолар төзү, судноларга һәм механизмнарына техник хезмәт күрсәтү, транспорт электр җиһазлары, машиналар төзелеше технологиясе, икътисад, бухгалтерлык хисабы һәм контроль. Техникумны тәмамлаучылар арасында — А.М.Горький исем. Яшел Үзән суднолар төзү з-ды директоры Е.М.Виноградов. Техникум 2011 елда ябыла.

**ЯШЕ́Л ҮЗӘ́Н ТАРИХИ́-МӘДӘНИ́ МИРА́С МУЗЕЕ́**, муниципаль музей. 2005 елда ачыла. Ике катлы аерым бинада урнашкан. 7 залдан торган экспозициянең мәйданы — 380 *м*², музей фонды 12 мең саклау берәмлеге тәшкил итә. «Яшел Үзән каһарманнары» бүлегендә Бөек Ватан сугышында катнашкан Советлар Союзы Геройлары С.М.*Бендиков*, Н.Д.*Волостнов*, И.М.*Засорин*, Н.А.*Катин*, М.Е.*Колчанов*, Г.Г.*Морзаханов*, И.А.*Норкин*, А.П.*Панфилов*, В.А.*Петров*, Н.Л.*Соболев*, Н.С.*Сафин*, В.Х.*Хажиев*, Х.З.*Хәйруллин*, Х.Х.*Хәсәнов*; Дан орденының тулы кавалеры Я.М.*Харитоновларның* орден-медальләре, фронт хатлары урын алган. Шәһәр пр-тиеләрнең Бөек Ватан сугышы елларындагы эшчәнлегенә аерым бүлек багышланган. 3 нче залда музей фондларындагы экспонатлардан файдаланып вакытлы күргәзмәләр оештырыла. Икенче каттагы экспозицияләр шәһәр пр-тиеләре һәм район тарихы турында сөйли.

Ел саен Җиңү көне (9 май), Балаларны яклау көне (1 июнь), Белем көне (1 сент.) билгеләп үтелә.

**ЯШЕ́Л ҮЗӘ́Н УРМАНЧЫЛЫГЫ́**, Яшел Үзән р-ны терр-ясендә урманнарны файдалану, саклау, ышыклау, яңадан утырту өлкәсендә идарә эшләрен алып бара. 1960 елда Зеленодольск урман хуҗалыгы буларак оештырыла; 2007 дән хәзерге исемендә. Гомуми мәйданы 26356 *га*, 3 урманчылык: Әйшә (8503 *га*), Яшел Үзән (8661 *га*), Кызыл Октябрь (9192 *га*) участокларыннан тора. Урман б-н капланган мәйдан 24794 *га* тәшкил итә, ш.и. ылыслы токымнар — 13682 *га*, йомшак яфраклылар — 10382 *га*, каты яфраклылар 698 *га* били. Урман барлыкка китерүче төп токымнар: нарат (46,3%), Европа чыршысы (7,5%), каен (28,1%), юкә (10,3%), усак (3,1%), сабакчалы имән (2,8%) һ.б. Урман типларыннан: мүкле, куаклы нәратлыклар, күрәнле каенлыклар өстенлек итә. Яшь урманнар — 10,9%, урта яшьтәгеләр — 37,0%, өлгереп килүчеләр — 18,7%, өлгергәннәр һәм картайганнар — 33,4% урман мәйданын алып тора. Гомуми агач запасы — 6886,9 мең *м*³, ш.и. өлгергән һәм картайган агачлар — 2560,2 мең *м*³ (37,2%). 2010–17 елларда 147 *га* мәйданда ышыклау утыртмалары булдырыла. Утырту материалы үстерү питомнигы, ш.у. урман янгыннары б-н көрәшү өчен янгын станциясе эшли.

**ЯШЕ́Л ҮЗӘ́Н ФАНЕ́РА ЗАВОДЫ́**, агач эшкәртү сәнәгате пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 530 кеше (2017). 1898 елда Яшел Үзән тимер юл станциясе посёлогында америка сәнәгатьчесе Э.В.Ропс тарафыннан нигезләнә. Такта материаллары, мичкә такталары, шырпы таякчыклары (Англиягә җибәрелә) эшләп чыгарыла. 1916 да Петроград-Брагор җәмгыятенә сатыла, соңрак «Рус фанерасы» төньяк фанера һәм агач эшләре заводлары» АҖ составына кертелә. 1918 дә национализацияләнә; 1923 тән фанера җитештерүгә күчә. Бөек Ватан сугышы чорында По-2 (У-2 ВС) самолётлары фюзеляжларын тышлау өчен фанера чыгара. Шуннан соңгы елларда пр-тиедә этаплы реконструкция уздырыла: 1948 дә төп технол. җиһазлар алыштырыла, 1967–68 дә җитештерү һәм ярдәмче эшләр мәйданнары шактый киңәйтелә, 1974 тә яңа йомшарткыч станоклар урнаштырыла, чималны күчерү, кайнату казаннарында һәм киптерү урыннарында эшкәртү процесслары механикалаштырыла, пар б-н эшләгән киптерү агрегатлары газга күчерелә, 1980 еллар уртасында шпон йомшарту һәм кисү линияләре, заманча киптерү җайланмалары гамәлгә кертелә. 1990 елларда чит илләрдә эшләнгән җиһазлар б-н яңартып коралландырыла. 1965 тән хәзерге исемдә. 1991 дә завод — аренда, 1996 да дәүләт унитар пр-тиесе итеп үзгәртелә. 2001 дән — АҖ. Аның составында — төп (йомшарту-киптерү, чимал, ябыштыру-кисү) һәм ярдәмче (электр карлары, ремонт-механика, пар энергетикасы хуҗалыгы һ.б.) җитештерү цехлары. Пр-тие продукциясенең 90% тан артык өлеше — карбамид синтетик сумалалар б-н ябыштырылган, 3 *мм* дан 21 *мм* га кадәр калынлыктагы һәм 1525x1525 *мм* зурлыктагы каен фанера. Югары физик-механик үзлекләре һәм текстурасы аны сәнәгатьнең төрле өлкәләрендә һәм музыка кораллары җитештерүдә куллану мөмкинлеге бирә. Еллык җитештерү күләмнәре (*м*³): 1929 да — 3719, 1938 дә — 10286, 1970 тә — 56000, 1999 да — 34804. Хәзерге вакытта җитештерү куәтләре елга 60 мең *м*³ продукция эшләп чыгаруга сәләтле. Җитештерелгән фанераның 70% чамасы Мисырга, Англиягә, Германиягә, АКШка, Австриягә, Венгриягә, БДБ илләренә һ.б.га җибәрелә.

Заводта ш.у. киселгән фанера продукциясе, рәшәткә, йорт җиһазлары әзерләмәләре, йомычкалар, техник сумала, пычкы материаллары чыгарыла. Завод өчен агач — Мари Эл Респ-касы, Татарстан, Киров һәм Пермь өлкәләре, синтетик сумала Түбән Тагил, Пермь өлкәсенең Губаха шәһәре пр-тиеләреннән китерелә. Я.Ү.ф.з. Россиянең агач эшкәртүче пр-тиеләре арасында беренче булып халыкара ИСО 9002 сыйфат сертификаты ала. Югары казанышлары өчен заводка «Россия икътисады лидеры» исеме бирелә (1995), халыкара Сәүдә лидерлары клубының «Технология һәм сыйфат өчен» призы тапшырыла (2001). Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре хөкүмәт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1 кеше — Ленин ордены, 9 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 10 кеше — «Почёт билгесе», 3 кеше төрле дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары б-н бүләкләнә. Завод җитәкчеләре арасында — Э.В.Ропс (1898–1916), М.Я.Курочкин (1922–?), И.Ф.Плоппа, А.П.Котельников, А.Я.Фёдоров (1965–73, 1976–85), Б.А.Головлев (1973–76), В.А.Агапитов (1985–95), Г.Д.Бурнаев (1995–2000), А.А.Когогин (2000–07), А.Л.Скоробогатый (2015–17), Э.Ю.Егоров (2017 дән).

**ЯШЕ́Л ЧЫПЧЫКЛА́Р** (Chloris), тау чыпчыклары семьялыгыннан кошлар ыругы. 2 төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк-Көнбатыш Африкада очрыйлар. ТР терр-ясендә бер төре — гади яшел чыпчык (Ch. chloris) бар. Якты яфраклы урманнарда, елга үзәннәрендә, ш.у. бакча һәм паркларда яши. Гәүдәсенең озынлыгы 15 *см* тирәсе, авырлыгы 25–35 *г*. Ата кош зәйтүнсыман яшел, түше сары-яшел, ана кош караңгырак төстә.Томшыгы зур, формасы конуссыман. Күчмә кош. Март-апрельдә килә. Оясын агач, еш кына яшь чыршы ботакларына кора. Кышлар өчен китү вакыты — октябрьгә кадәрге чор. Кызгылт тимгелле һәм аз гына зәңгәрсу яки яшькелт төсмерле 4–6 ак йомырка сала. Җиләкләр һәм майлы культураларның (эт какысы, киндер, көнбагыш) орлыклары б-н туклана, балаларына бөҗәкләр ашата.

**ЯШЕЛЧӘ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы янында. 2010 елда 54 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1932 дә Кече Салтык авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 140, 1949 да — 147, 1958 дә — 129, 1970 тә — 120, 1979 да — 73, 1989 да — 65, 2002 дә — 53 кеше.

**ЯШЕЛЧӘ́ КУЛЬТУ́РАЛАРЫ**, яшелчә алу өчен үстерелә торган үсемлекләр (яфраклар, сусыл җимешләр, суганчалар, тамыразыклар). ТРда 50 дән артык Я.к.ның 30 төре үстерелә; иң киң таралганнары 10 семьялыкка карый: кәбестәчәләр — кәбестә, гәрәнкә, шалкан, редис, керән, кресс-салат; чатырчалар — кишер, петрушка, сельдерей, гәзнич, укроп; алабутачалар — чөгендер, шпинат; кабакчалар — кыяр, патиссон, кабак, ташкабак, кавын, карбыз; паслёнчалар — томатлар, кузаклы борыч, баклажан; суганчалар — суган, сарымсак; кузаклылар — борчак, фасоль, ногыт борчагы; кашкарыйчалар — салат, латук, эвидий, гади һиндыба; оешма чәчәклеләр — салат; карабодайчалар — рәваҗ, кузгалак.

Продуктив органнарына карап, Я.к. яфраклыларга (кәбестә, укроп, яфрак петрушка һәм сельдерей, салат, шпинат), җимешлеләргә (томат, кыяр, кабак, патиссон, ташкабак, борыч, баклажан,), яшелчәлеләргә (борчак, фасоль), суганлыларга (суган, сарымсак), тамыразыклыларга (шалкан, редис, торма, кишер, чөгендер, петрушка, гәзнич, сельдерей) бүленәләр. Я.к.на иртә өлгерә торган бәрәңге, шикәр кукурузы, гөмбәләр (шампиньон) керә. Яшәү озынлыгы буенча бер-, ике- һәм күпьеллык Я.к.на бүленәләр. Берьеллыклар яшәү циклын (орлыктан орлыкка кадәр) 1 ел эчендә тәмамлыйлар һәм тулысынча үләләр (кузаклылар, кабакчалар, редис, укроп, томат). Икееллыклар 1 ел эчендә азык булarak кулланыла торган продуктив органнар, 2 нче елда орлыклар барлыкка китерә (башлы суган, сарымсак, тамыразыклар — редистан тыш, кәбестә — чәчәкле һәм пекин кәбестәсеннән тыш һәм ратишок). Күпьеллык Я.к. (рәваҗ, кузгалак, спаржа, эстрагон, батун суган, исле суган, тасма кыяклы суган) күп тапкырлар (ел саен) җимеш бирәләр (орлык барлыкка китереп). Я.к.н Татарстанның барлык районнарында, башлыча шәхси бакчаларда, күп өлешен шәһәр яны зоналарында үстерәләр. Товарлыклы Я.к., нигездә, Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә шәһәр яны зоналарында җитештерелә. Иң зур мәйданнарда кәбестә, кишер, чөгендер, суган, ябык грунтта кыяр, томат, суган (яшел культура буларак), шампиньон үстерәләр. Ш.у.к. *Яшелчәчелек*.

*И.Н.Афанасьев.*

**ЯШЕЛЧӘЧЕЛЕ́К**, 1) Үсемлекчелекнең *яшелчә культуралары* яшелчәләрен һәм орлыкларын, орлыклык материал җитештерү б-н шөгыльләнә торган тармагы; 2) яшелчә культуралары биологиясен һәм аларны үстерү алымнарын өйрәнүче, яшелчәчелек продукциясе алу өчен интенсив технологияләр эшләүче фән.

Борынгы Кытайда, Мисыр, Греция, Римда яшелчә культураларын үстерү турында беренче тапкыр б.э.к. 3 йөздә, борынгы славяннар терр-ясенә карата 5 йөздә искә алына. 15 йөзгә Я. Русьта шул заман өчен югары дәрәҗәгә ирешә. 19 йөз уртасыннан бәрәңге төп бакча культурасына әверелә, Я. үсеше акрын темплар б-н бара, әмма крәстиян гаиләләренә үзләренең туклану ихтыяҗларын канәгатьләндерергә мөмкинлек бирә. Казан губернасы татарларында суган иң таралган яшелчә культурасы була, ул кечкенә бакчаларда үстерелә. Бар җирдә дә диярлек, татарлар яшәгән төньяк һәм көньяк-көнчыгыш районнардан тыш, бакча культурасы — кабак үстерелә.

Соңрак бакчаларда кишер, чөгендер, кәбестә, сарымсак, торма, гәрәнкә, кыяр үстерелә башлый. Культурадагы яшелчәләр арасында шалкан аерым урын били. Аны барлык татар авылларында диярлек, урман һәм урман-далалы зоналарда кырларда, сирәгрәк бакчаларда үстерәләр. Очраклы урман янгыннарыннан соң урманнардан чистартылган участокларда чәчү әйләнеше шалкан чәчү б-н башлана. 19 йөзнең 2 яртысында бәрәңге киң таралу сәбәпле, шалкан чәчү кими.

Казан губернасында яшелчә культураларының мәйданнары 1913 елда 1,1 мең *га*, 1920 дә 1,3 мең *га* тәшкил итә. Я. үсеше һәм үстерелә торган культураларны урнаштыру стихияле характерда була. Я. б-н сәүдә итү нигездә Казан яны зонасында үсә. 1928 дә яшелчә культуралары 6,4 мең *га* да үстерелә. А.х.н күмәкләштерүдән соң, Я. интенсив үсеш ала. 1932 дә 12,1 мең *т* яшелчә хәзерләнә. Алга таба яшелчә җитештерү өзлексез үстерелә һәм аларны дәүләт сатып алуы арта.

Татарстанда 1940–2016 елларда яшелчә җитештерү һәм дәүләт сатып алуы, мең *т*

| Ел | Җитештерү | Дәүләт сатып алулары (2000 нән — а.х. пр-тиеләре тарафыннан сатылу) |
|---|---|---|
| 1940 | 94,7 | 17,7 |
| 1960 | 100,4 | 22,6 |
| 1970 | 144,6 | 53,3 |
| 1980 | 197,0 | 113,0 |
| 1990 | 218,7 | 169,0 |
| 2000 | 228,8 | 75,6 |
| 2006 | 325,7 | 58,8 |
| 2016 | 286,0 | 137,0 |

ТРда Я. башлыча кулланылучылык характерында була. 2016 дан шәхси бакчаларда 286 мең *т* яшелчә үстерелә. Иң күп яшелчә Лаеш р-нының «Нармонка», Яшел Үзән р-нының «*Майский*», Тукай р-нының «*Ворошиловский*» һәм «*Весенний*», Түбән Кама р-нының «Түбән Кама» а.х. пр-тиеләрендә җитештерелә. Татарстанда 50 дән артык яшелчә культурасы игелә, шулардан а.х. пр-тиеләрендә иң киң таралганнары — кәбестә, кишер, аш чөгендере, суган (башлы һәм яшел суган), кыяр, томат. Шәхси бакчаларда, нигездә, томат, кыяр, кишер, аш чөгендере, башлы суган, сарымсак, редис, ташкабак, кабак һәм яшел культуралар үстерелә. Татарстанда җитештерү өчен «Россорткомиссия» ФДИнең Татарстан ф-лы тәкъдим иткән исемлеккә яшелчә культураларының 120 дән артык сорты һәм гибриды кертелгән (Урта Идел буе төбәкләре буенча Дәүләт реестрына кергәннәре). ТРда Я. тармагын Татарстан «Татплодоовощпром» коммерцияле җитештерү концерны җитәкли, ул «Татсортсемовощ» берләшмәсе б-н бергә а.х. пр-тиеләрен һәм халыкны яшелчә культуралары орлыклары б-н тәэмин итә (пр-тиеләр үзләре орлык җитештерми).

Татарстанда Я.не үстерүгә иң күп өлеш керткән галимнәр, а.х. оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләре: П.П.*Гусев*, А.А.Срослова, С.С.*Нилов*, Н.Ф.Атрохов, С.З.Зиннәтов, С.К.*Гыйматдинов*, Р.Ш.*Зыятдинов*, И.Н.Афанасьев, С.Г.Садриев, С.М.Кротов, В.А.Демидович, В.К.Осипов һ.б.

*Әд.:* Матвеев В.П., Рубцов М.И. Овощеводство. М., 1985; Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX вв.). К., 1995.

*И.Н.Афанасьев.*

**«ЯШЕ́Н»**, сатирик, юмористик журнал. 1908 елның августыннан 1909 нең 24 июненә кадәр айга 2 тапкыр Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 10 саны чыга. Нашире, мөхәррире һәм рәссамы — Г.Камал. Журналны оештыруда Г.Тукай, Ф.Әмирхан катнаша. Актив авторлары арасында — Ф.Әмирхан,




«Яшен» журналы.

Г.Камал, И.Кулиев, Ә.Максуди, А.Саттаров, М.Укмасый. Редакция демократик юнәлеш ала, азатлык һәм алгарыш, татар милләтен агарту идеяләрен пропагандалый. Патриархаль тормыш тәртибе яклылардан, ишаннарның икейөзлелегеннән, вак кибетчеләрнең саранлыгыннан, дини-консерватив матбугаттан («Бәянелхак», «Дин вә мәгыйшәт» һ.б.) көлә. Күп урын шигырьләр һәм фельетоннарга, бигрәк тә Г.Тукай әсәрләренә («Я.»дә шагыйрьнең беренче тапкыр 22 шигыре һәм 25 проза әсәре басыла) бирелә. Журнал рәсемнәргә бай була, рәссамы — Ф.Әмирхан (65 рәсеме басылган). Акча булмау сәбәпле чыгудан туктый.

*Әд.:* Гали Б. «Молнией «Яшен» сверкает в облаках народных бед...» // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2007. № 1.

**ЯШЕНЛЕ́ ЯҢГЫ́Р**, атм. күренеше, бу вакытта куәтле өем-яңгыр болытлары яки болытлар б-н җир өсте арасында көчле электр разрядлары барлыкка килә — яшен яшьни, күк күкри. Я.я. вакытында җилләп-давыллап яңгыр, кайвакыт боз ява, көчле җил күзәтелә. Атм. фронтларында, ягъни җылы һәм салкын *һава массалары* чикләре арасында фронталь һәм, нигездә, дымлы һаваның җирле җылынуы нәтиҗәсендә төштән соңгы сәгатьләрдә барлыкка килүче масса эчендәге Я.я.га аерып йөртәләр. ТРда елына уртача 23–32 көн Я.я. яву күзәтелә, гадәттә, апрельдән сентябрьгә, кайбер елларда кышын да билгеләнә. Я.я. апрельдә уртача ике елга бер, майдан августка кадәр — айга 3–9 көн, сентябрьдә елга бер тапкыр күзәтелә. Я.я. уртача 2 сәгатькә, сирәк очракларда 10–15 сәгатькә сузыла. Боз ешрак май-июньдә ява, елга уртача 1–2, максимум 3–8 тапкыр була.

*Әд.:* Климат Татарской АССР. К., 1983; З а в о д ч е н к о в А.Ф., П е р е в е д е н ц е в Ю.П. Грозы Урала и Поволжья, их прогноз. К., 1989.

*М.А.Верещагин.*

**«ЯШЕРЕ́Н ӘДӘБИ́ ТҮГӘРӘ́К»**, 1902–05 елларда Казанда «*Мөхәммәдия*» мәдрәсәсендә эшли. Татар уку йортларында мәдәни-тамаша чаралары тыелган шартларда газета уку өчен яшерен түгәрәк буларак барлыкка килә. Лидерлары: Ф.Әмирхан, И.Әмирхан, И.Бикколов, Г.Сөләйманов, М.Укмаси; актив әгъзалар арасында ш.у. В.Бәхтияров, К.Патии була. 1903–04 тә Ф.Әмирхан җитәкчелегендә төрле яшьтәге шәкертләрне берләштергән җәмгыятькә әверелә. Түгәрәк әгъзалары әдәби кичәләр уздыралар, яшерен кулъязма «Тилгән» г-тасы чыгаралар.

*Әд.:* А м и р х а н о в Р.У. Татарский народ и Татарстан в начале XX в. К., 2005.

**ЯШЕРЕ́Н ЧИШМӘ́**, Казансу елгасы ярында, Казан Кремленең төньяк дивары янында, Яшерен манарадан (Тайницкий) 100 *м* чамасы көнчыгыштарак урнашкан кизләү. 1552 елгы вакыйгалар буенча билгеле. Иван Грозный гаскәрләре Казанны камап алгач, шәһәрне саклаучылар яшерен юлдан шул чишмәгә эчәргә яраклы суга йөргәннәр (аларның башка су чыганакларына үтү мөмкинлеге булмый). Елъязмаларда теркәлгәнчә, Иван IV Казан халкының кайдан су алуы б-н кызыксынган. Йомышлы татарлар аңа Нурали (рус елъязмаларында — Мурали) капкасы янында җир астындагы таш баскычтан казанлыларның чишмәгә йөрүләрен хәбәр итәләр. Патша җир асты юлын шартлатырга әмер бирә (Патша китабында күрсәтелгәнчә, Болак елгасы ягыннан, *Даир мунчасының* таш бинасыннан казып керәләр). 10 көннән соң казу эше тәгәлләнә. Шартлату алдыннан (1552 елның 4 сентябре) руслар кальга диварлары янынннан тупларны алалар һәм берникадәр үзләре дә чигенәләр (шартлау көче бик зур була дип уйланыла). Казанлылар Иван IV камауны туктата дип уйлыйлар һәм дивар өсләренә күтәреләләр.

Львов елъязмасында: «Һәм ут кабынды, шәһәр диварының өчтән бер өлешен алып ташлады, бик күп татар кырылды», — дип языла. «Казан тарихы»нда бу вакыйга детальләштереп бирелә: шартлау бүрәнәләрне, ташларны һәм кешеләрне төрле якка «унлаган һәм егермеләгән чакрымнарга» ташлый. Чишмәгә илтүче яшерен юл җимерелә. Казан кальгасындагы Нурали капкасын руслар «Яшерен капка» дип атый башлыйлар. Чишмә 20 йөз уртасына кадәр тибә. Проф. Н.П.Загоскин аны 1895 тә тасвирлый. 1913 тә Н.А.Спасскийның «Ватанны өйрәнү очерклары»нда («Очерки по родиноведению») Я.ч. турында «Татарлар тарафыннан хөрмәт ителгән «Яшерен капка» астында кальгадан илтүче яшерен юл бар, ләкин чыгу урыны күмелгән» дип әйтелә. Чишмә суын мөселманнар сихәтле дип исәпләгәннәр. 1954 тә Н.Ф.Калинин тарафыннан Яшерен манара янында археол. казу эшләре алып барылганда аның төньяк почмагында яртылаш күмелгән җир асты юлының башланган урыны табыла. 1957 дә, Куйбышев сусаклагычын төзегәндә, Я.ч. күмелә. 2000 дә Яшерен манарадан көнчыгыштарак казу эшләре башкарыла, ләкин хәзерге калын катлам астында фәкать Казансу елгасының су йөртүчән пласты гына ачыклана.

*Әд.:* Р ы б у ш к и н М.С. Краткая история города Казани. К., 1834; З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Казанская история. М.–Л., 1954; К а л и н и н Н.Ф. Казань: Ист очерк. К., 1955.

*М.В.Недорезов.*

**Я́ШИН** Георгий Филиппович (17.4.1907, Казан губ., Казан өязе Бәрле а. – 12.9.1957, Казан), Сов. Союзы Герое (21.7.1944), гв. өлкән лейтенанты. 1929–31 елларда Кызыл Армиядә Беренче татар укчы полкында хезмәт итә. 1932–41 дә НКВД органнарында эшли. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, взвод командиры ярдәмчесе, 134 нче гв. укчы полкның (21 нче армиянең 45 нче гв. укчы дивизиясе) укчы ротасында политрук. Ленинград фронты гаскәрләре составында Выборг һөҗүм операциясендә катнаша (1944). 1944 нең 10 июнендә Карелия муентыгында шәһәр тибындагы Белоостров посёлогы янында батырлык күрсәтә: беренче булып һөҗүмгә күтәрелә, дошман траншеясенә бәреп керә, ике сугышчы б-н гранаталар ыргытып дзотны юк итә; сугышта яраланган рота командирын алмаштыра; яралана, әмма сугышуын дәвам итә. Демобилизацияләнгәннән соң (1945) Казанда яши, ТАССР Эчке эшләр министрлыгының Янгыннан саклау идарәсендә эшли. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Ленинград өлкәсенең Выборг районындагы посёлокка Герой исеме бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*



Г.Ф.Яшин.

**Я́ШИНА** Галина Игънатьевна (5.8.1928, Казан), вет. табибе, вет. фән. д-ры (1986). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), Псков өлкәсендә районара вет. бактериол. лаб-ясе мөдире булып эшли. 1959–2008 елларда Казан вет. медицинасы академиясендә, анатомия каф. доценты (1979 дан). Хезмәтләре а.х. терлекләренең эчәклек һәм корсак куышлыгы нервлары макро-микроморфологиясен, перитонит, бронхлар ялкынсынуы һ.б. авырулар очрагында физиотерапия чараларының дәвалау тәэсирен өйрәнүгә карый. Перитонитны карын нервларына лазер б-н тәэсир итеп дәвалау ысулын эшли.

Х е з м.: Морфофункциональная характеристика нервов брюшины // Материалы науч.-произв. конф. по проблемам ветеринарии и животноводства. К., 1994.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

**«ЯШЬ АВЫ́Л»**, айлык иҗтимагый-сәяси журнал. РЛКСМ ҮК каршындагы Татар-башкорт бюросы органы. 1925 елда Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә, беренче саны 1925 нең апрелендә басыла. Мөхәррире — С.Садыйков. «Яшәсен эшче һәм крәстиян берлеге!» лозунгы б-н чыга. Басманың максаты — авыл яшьләрен социализм рухында тәрбияләү һәм агарту. Журнал битләрендә коммунистик тәгълимат, а.х.н рациональ алып бару турындагы мәкаләләр, яшь авторларның (С.А.Азамат, М.Бикбулат һ.б.) әсәрләре дөнья күрә.

**«ЯШЬ ЙӨРӘ́К»**, яшьләрнең иҗтимагый-сәяси газетасы. РКСМның Башкортстан губерна ком-ты органы. 1921 елның августыннан 1922 нең июленә кадәр Эстәрлетамак шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. «Яшьләр, горурлар, көчлеләр, кыюлар, аталарның эшен тәмамлыйк!» лозунгы б-н чыга. Мөхәррире — Х.Лотфи. СССРдагы яшьләрнең иҗтимагый-сәяси тормышы яктыртыла, шул ук вакытта төп игътибар татар яшьләре хәрәкәтенә бирелә. Яшьләр оешмалары форумнары (4 нче Бөтенсоюз яшь коммунистлар съезды һ.б.) турындагы хисаплар басыла. Чит илләрдәге тормыш турындагы мәкаләләр «Шәрекъ яшьләре тормышыннан», «Чит ил яңалыклары» һ.б. рубрикаларда урнаштырыла. Әдәби бүлектә Д.Юлтый һ.б. яшь авторларның хикәяләре, шигырьләре басыла. БАССР башкаласы Эстәрлетамактан Уфага күчерелгәч, газета чыгудан туктый.

**«ЯШЬ КОММУНА́Р»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. РКСМның Әстерхан губерна ком-ты Шәрекъ бюросы органы. 1920 елның июненнән 1921 нең февраленә кадәр Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. «Бөтендөнья эшче яшьләре берләшегез!» лозунгы б-н чыга. Мөхәррире — К.Габдуллин, Х.Ибраһимов. Газетаның һәр саны үз эченә чит ил һәм гомумроссия яңалыклары, җирле хәбәрләр һ.б. рубрикаларны ала. Зур игътибар Гражданнар сугышында катнашкан яшьләргә, хәрби-патриотик тәрбиягә бирелә; газета хәрби хезмәткә 16 яшьтән алы-

ныргa мөмкинлеге турындагы мәсьәләне күтәрә. Халык хуҗалыгын торгызуда, мәдәни төзелештә яшьләрнең роле; Әстерхан өлкәсенең 2 нче партиясез яшьләр конференциясе, 3 нче Бөтенроссия коммунистик яшьләр съезды һ.б. эше яктыртыла. Яшь авторларның әсәрләре басыла.

**«ЯШЬ КОММУНА́Р»**, яшьләрнең иҗтимагый-сәяси, әдәби газетасы. ВЛКСМның Башкортстан өлкә ком-ты органы. 1920–41 елларда Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Исеме үзгәрә: 1920–22 дә — «Шәрекъ яшьләре», 1923–30 да — «Яшь юксыл», 1930–41 дә — «Я.к.» Чыгу ешлыгы төрлечә була, күбесенчә атнага бер тапкыр басыла. Мөхәррирләре — Г.Кушаев, З.Каипкулов, Г.Сиражетдинов, Г.Амантай, С.Тимербулатов, Х.Мөхәммәдьяров һ.б. Актив авторлар арасында — Г.Габдрахманов, Г.Галантай, Х.Кәримов, Д.Юлтый, М.Йосыпов һ.б. Даими рубрикалары: «Дин һәм коммунизм», «Фән һәм техника», «Авыл хуҗалыгы», «Балалар почмагы» һ.б. Редакция укучыларны совет һәм чит ил яшьләре тормышы б-н таныштыра. Күмәкләштерү һәм индустрияләштерү барышы, төбәктә нефть чыганакларын эшкәртү киң яктыртыла. Танып белү материаллары (аерым алганда, эсперанто дәресләре сериясе) басыла. А. х. буенча гамәли киңәшләр бирелә. Татар вакытлы матбугаты турындагы аналитик һәм стат. материаллар, ш.и. И.Рәми мәкаләләре дөнья күрә. 1930 да иҗтимагый-сәяси материалларның өлеше арта, әдәби әсәрләрнең саны кими. Г.Гомәров, С.Исхаков, К.Мортазин, М.Фәиз, Б.Фәйзи, Д.Юлтый шигырьләре, яшь авторлар ш.и. М.Марат, А.Ихсани һ.б.иҗаты турында тәнкыйть язмалары басыла. Газета татар телендә «Кызыл галстук», башкорт телендә «Башкортстан яшьләре» кушымталары б-н чыга. Бөек Ватан сугышы башлангач, газета чыгудан туктый.

**«ЯШЬ КОММУНА́Р»**, атналык балалар газетасы. ВЛКСМ ҮКның оештыру бюросы һәм ВЛКСМ шәһәр ком-ты органы. 1932–35 елларда Свердловск шәһәрендә нәшер ителә. Башта текстлар татар һәм рус телләрендә, 1934 нең 12 мартыннан фәкать татар телендә генә басыла, барысы 100 гә якын саны чыга. «Эшче эше өчен көрәшкә әзер бул!» лозунгы б-н дөнья күрә. Төрле елларда мөхәррирләре — С.Князев, И.Йосыпов, К.Биков. Басманың максаты — коммунистик идеалларны пропагандалау, үсеп килүче буынны Ватанга карата мәхәббәт, дуслык, гаделлек рухында тәрбияләү. Газетада СССР һәм чит илдәге вакыйгалар, чит ил балалар оешмалары эшчәнлеге, совет укучылары тормышы яктыртыла. Укучыларны эре пр-тиеләр, ш.и. «Уралвагонстрой», «Уралмаш» һ.б. төзелеше барышы б-н таныштыра.

**«ЯШЬ КОММУНИ́СТ»**, газета; к. «*Яшьләр дөньясы*».

**«ЯШЬ КӨЧ»**, газета; к. «*Яшьләр дөньясы*».

**ЯШЬ КӨЧ** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 12 *км* көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 31 кеше (руслар, татарлар) яши. 1920 дә нигезләнә. Оешкан көненнән — ТАССРның Арча кантоны Сабакай волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Казан, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 99, 1958 дә — 183, 1970 тә — 104, 1989 да — 36, 2002 дә — 25 кеше.

**«ЯШЬ ЛЕ́НИНЧЫ»**, газета; к. «*Сабантуй*».

**«ЯШЬ ПЕДАГО́Г»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби-пед. журнал. ВКП(б) һәм ВЛКСМның Казан Шәрекъ пед. ин-тындагы ячейкалары органы. 1926 елның октябреннән 1929 га кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 7 саны чыга. Мөхәррире — Г.*Шәрәф*. Зур игътибар наданлыкны бетерү, татар телен адм. эшчәнлектә, фән һәм мәдәнияттә куллану, ш.и. татар графикасын бердәйләштерү, яңалифне кертү, татар фәнни терминологиясен үстерү проблемаларына бирелә. Татарларда фәнне үстерү, аерым алганда, Г.Ибраһимов, Шәриф ахун (беренче бәет җыючылардан берсе) һ.б. эшчәнлеге турындагы язмалар басыла. Татар этнографиясе, татар пед. фикере тарихы проблемаларын өйрәнү мәсьәләләре турында фикер алышына. Казанның әдәби тормышы, татар пролетар әдәбияты формалашу турындагы язмалар, Г.Рәхим, Х.Халитова шигырьләре, Г.Кашшаф һ.б.ның хикәяләре басыла. Соңгы санның текстлары гарәп һәм латин графикасында дөнья күрә.

*З.З.Гыйләҗев.*

**«ЯШЬ СТА́ЛИНЧЫ»**, газета; к. «*Татарстан яшьләре*».

**«ЯШЬ ЭШЧЕ́»**, айлык иҗтимагый-сәяси, фәнни, әдәби, рәсемле журнал. ВЛКСМ ҮК каршындагы Татар-башкорт бюросы органы. 1922 елның апрелендә Шәрекъ яшьләре үзәк бюросы тарафыннан оештырыла, атналык «Яшь эшче» г-тасы җирлегендә барлыкка килә. 1922 нең декабреннән 1928 нең мартына кадәр Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә, барысы 64 саны чыга. Мөхәррирләре — М.Парсин, С.Садыйков, ш.у. составында С.Таипов, М.Максуд, Н.Гыйбадуллин, Б.Мансуров, Г.Кушаев, Г.Ильясов һ.б. булган мөхәрририят. СССР халыклары Үзәк нәшрияты тарафыннан чыгарыла. Актив авторлары арасында — Ф.Агиев, С.Атнагулов, З.Бәшири, М.Гафури, Ш.Зәбиров, Г.Ибраһимов, Н.Исәнбәт, Х.Курмаев, Х.Лотфи, Б.Мансуров, Г.Нигъмәти, Һ.Такташ, Г.Толымбайский һ.б. Журнал марксизм-ленинизм идеяләрен пропагандалый, илдә һәм чит илләрдә яшьләр хәрәкәтен үстерүне яктырта. Партия һәм комсомол форумнары (аерым алганда, Коминтернның 3 нче Яшьләр конгрессы барышы яктыртыла) материаллары, башлап язучы һәм күренекле авторларның (З.Бәшири, М.Җәлил, М.Кәрим, Х.Курмай, Г.Кутуй, Ш.Маннур, Н.Мортазина, Г.Толымбайский, Д.Фәтхи һ.б.) әдәби әсәрләре басыла. 1925 тән әдәби бүлек күләме кыскара, иҗтимагый-сәяси язмаларның өлеше арта.

*З.З.Гыйләҗев.*

**«ЯШЬ ЮКСЫ́Л»**, газета; к. «*Яшь коммунар*».

**«ЯШЬЛӘ́Р»**, газета; к. «*Кызыл Урал*».

**ЯШЬЛӘ́Р**, к. *Молодёжный*, Әлмәт р-ны.

**ЯШЬЛӘ́Р** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кече Ирнә елгасының (Дала Зәе бассейны) югары агымы буенда. 1920 елларда нигезләнә. Оешкан көнненнән — ТАССРның Чаллы кантоны Сарман волостенда. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1926 да — 80, 1938 дә — 117, 1949 һәм 1958 дә — 98 әр, 1970 тә — 95, 1979 да — 58, 1989 да — 16, 2002 дә — 11 кеше.

**«ЯШЬЛӘ́Р ДӨНЬЯСЫ́»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. РКСМның Уфа губерна ком-ты каршындагы Татар-башкорт бюросы органы. 1920–21 елларда Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Исеме үзгәрә: 1920 нең 13–27 февралендә — «Яңа көч», 1920 нең 28 маеннан 7 октябренә кадәр — «Яшь коммунист». Мөхәррирләре — Х.Гомәров, Т.Имаметдинов, М.Солтанов. Пропаганда характерындагы, яшьләрне интеллектуаль үстерү һәм тәрбияләү темасына кагылышлы, Гражданнар сугышында катнашучылар батырлыгы турындагы материаллар дөнья күрә. Әдәби бүлектә яшь эшче һәм крәстияннәрнең беренче әдәби тәҗрибәләре, ш.и. Х.Гомәровның һ.б.ның сәяси шигырьләре басыла.

**«ЯШЬЛӘ́Р СӘХИФӘСЕ́»**, газета; к.«*Азат Себер*».

## ӨСТӘМӘЛӘР

**Бу бүлектә эшчәнлекләре иҗтимагый-сәяси, фәнни, социомәдәни һәм хуҗалык тормышының төрле тармакларына караган, Татар энциклопедиясенең алдагы томнары дөнья күргәннән соң исемнәре Генераль сүзлекчәгә кертелгән шәхесләр турында кыскача биографик мәкаләләр бирелә.**

**АБА́ШЕВ** Альмир Рәшит улы (6.12.1975, Казан), невролог, сәламәтлек саклау өлкәсе оештыручысы, мед. фән. канд. (2005), ТРның атказ. табибе (2016), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2014). Казан мед. ун-тын тәмамлый (1998). 2000–02 елларда Респ-ка клиник вертеброневрология үзәгендә бүлек мөдире, табиб невролог. 2002–03 тә «Обсерватория» балалар туберкулёз санаторие баш табибе. 2003–12 дә Респ-ка 3 нче клиник хастаханәсе баш табибе. 2012–19 да 2 нче Респ-ка клиник хастаханәсе баш табибе, бер үк вакытта, 2016–19 да, Казан ун-ты клиникасы (КФУның Мед.-сан. часте) баш табибе. Бер үк вакытта, 2009 дан, Казан мед. ун-тының иҗтимагый сәламәтлек һәм сәламәтлек саклауны оештыру, Казан мед. академиясенең неврология, рефлексотерапия һәм остеопатия, КФУның Фундаменталь мед. һәм биол. ин-ты гигиена һәм иҗтимагый сәламәтлек кафедраларында. 2019 дан ТР сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары. Фәнни тикшеренүләре йөрәк эшчәнлеге җитешсезлеге эпидемиологиясе, кискен коронар синдром, дислипидемиягә карый. Дәүләт бүләге «Медицина диагностикасында магнит-резонанс томографиясе ысулларын булдыру һәм куллану» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. ТР Медицина хезмәткәрләре ассоциациясе әгъзасы. Медаль б-н бүләкләнә.

**АБДЕЛХА́КОВ** Рөстәм Аббас улы (13.12.1955, Әлмәт ш.), терапевт, мед. фән. д-ры (2008). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1979), Казан шәһәре 1 нче клиник хастаханәсендә гастроэнтеролог булып эшли, бер үк вакытта, 1985 елдан, Казан мед. ун-тының госпиталь терапиясе кафедрасында. Хезмәтләре ашказаны һәм уникеилле эчәк җәрәхәте авыруын ачыклауга һәм дәвалауга карый. Европа гастроэнтерологлар ассоциациясе әгъзасы, Россия гастроэнтерологлар фәнни җәмгыяте вице-президенты

**АБДРАЗА́КОВ** Илдар Әмир улы (26.9.1976, Уфа), опера җырчысы (бас), БРның һәм ТРның халык артисты (2011, 2013). Уфа сәнгать ин-тын (М.Г.Мортазина классы) тәмамлый (1999). Башкорт опера һәм балет театры солисты (1994 елдан). Халыкара Елена Образцова музыка академиясендә сәнгать җитәкчесе (2014 тән). Төп партияләре: Фигаро, Мазетто, Лепорелло («Фигароның өйләнүе», «Дон Жуан», В.Моцарт), Родольфо («Сомнамбула», В.Беллини), Эскамильо («Кармен», Ж.Бизе), Ассур, Мостафа, Моисей, дон Базилио («Семирамида», «Алжирдагы Италия хатын-кызы», «Моисей һәм фараон», «Севилья чәчтарашы» Дж.Россини), Мефистофель («Фауст», Ш.Гуно), Аттила, Филипп II (шул исем. әсәр буенча, «Дон Карлос», Дж.Верди), Линдорф («Гофман әкиятләре», Ж.Оффенбах), Генрих VIII («Анна Болейн», Г.Доницетти), Кенәз Игорь (шул исем. әсәр буенча, А.Бородин), Борис Годунов (шул исем. әсәр буенча, М.Мусоргский), Сурин («Пики дамасы», П.Чайковский) һ.б. «Ёлки 1914» (реж. Т.Бекмамбетов) фильмында Ф.И.Шаляпин ролендә төшә. АКШ һәм Европаның зур опера труппалары б-н, ш.у. Европаның (Лондон, Берлин, Вена, Мюнхен, Роттердам) филармония оркестрлары б-н чыгышлар ясый. Россия, Италия, Чехия, Япония, Португалия, Мексика һәм АКШта соло концертлар бирә. Халыкара, бөтенроссия, респ-ка конкурсларында катнаша. РФ Театр эшлеклеләре берлегенең «Алтын битлек» («Золотая маска») Милли бүләге лауреаты (2013).

**АБДУЛКАДЫ́ЙРОВ** Габделхәй Кадыйр улы (10.1.1934, Буа р-ны Кырык Садак а. – 9.8.2011, Казан), партия, хуҗалык-хакимият, профсоюз эшлеклесе. Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1957). 1957 елдан Чынлы, Чүпрәле, Әгерҗе р-ннарында хакимият-хуҗалык, партия эшендә. 1969–81 дә КПССның Апас райкомы 1нче секретаре. 1981–97 дә Татарстан а.х. хезмәткәрләре профсоюзы өлкә ком-ты, Татарстан аграр сәнәгать комплексы хезмәткәрләре профсоюзы өлкә ком-ты рәисе, Профсоюзларның Татарстан өлкә ком-ты секретаре. 1971–82 дә ТАССР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Почёт Билгесе орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**АБДУ́ЛЛИН** Адел (Гадел) Илсөяр улы (29.7.1972, Казан), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2006), проф. (2017). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1995), шунда ук укыта (1995–2001). 2001–02 елларда Фрибург ун-тында (Швейцария) һәм Бөтендөнья интеллектуаль милек академиясендә (Женева, Швейцария) стажёр-тикшеренүче. 2002–10 да Россия дәүләт хокук академиясенең Казан ф-лында дәүләт-хокук фәннәре каф. мөдире. 2010–11 дә Казан ун-тының гражданлык һәм эшмәкәрлек хокукы каф. мөдире, 2011 дән халыкара һәм Европа хокукы каф. мөдире. Хезмәтләре халыкара хосусый хокук тарихы һәм методологиясе, Европа хокукы (чыганаклар, институтлар, система), интеллектуаль милекне халыкара-хокукый саклау, халыкара гавами хокукның теоретик мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**АБДУ́ЛЛИН** Әсәт Гыйният улы (2.3.1950, Чиләбе өлкәсенең Чесма р-ны Рәдүт а.), психолог, пед. фән. канд. (1997), психол. фән. д-ры (2006), проф. (2007). Чиләбе пед. ин-тын (1979), Ленинград ун-тын (1987), Магнитогорск пед. ин-тын (1996) тәмамлый. 1966–84 елларда Рәдүт авылы мәктәбендә, 1979 дан директор, 1985 тән Магнитогорск пед. уч-щесендә, 1994 тән Магнитогорск пед. ин-тында. 1995 тән «Магнитогорск металлургия комбинаты» АҖнең әйдәп баручы психологы, бер үк вакытта Магнитогорск техник ун-тының пед. һәм психол. кафедрасында. 2007 дән РМАнең Һөнәри белем бирү пед. һәм психол. ин-тында (Казан). 2009 дан Көньяк Урал ун-тының (Чиләбе ш.) психодиагностика һәм психол. консультация кафедрасында. Хезмәтләре тормыш иминлеге психологиясе, сәламәт яшәү, зарарланган терр-яләрдә яшәүчеләр психологиясе мәсьәләләренә карый.

**АБДУ́ЛЛИН** Раушан Әхмәт улы (26.6.1988, Түбән өлкәсенең Нариман а. – 8.8.2008, Көньяк Осетия Респ-касы, Цхинвал ш.), РФ Герое (9.9.2009, үлгәннән соң), рядовой. 2006 елдан РФ Кораллы Көчләрендә, Төньяк Кавказ хәрби округының махсус 10 нчы аерым бригадасы составындагы махсус 107 нче отрядның 2 нче ротасы сапёр-разведчигы. Россиянең Көньяк Осетиядәге тынычлык саклау көчләре составында 2008 нең 8 августында батырлык күрсәтә: отряд грузин гаскәрләренең беренче һөҗүмнәренә каршы тора; А. яралана, кул гранатомётыннан атып каршы як танкын сафтан чыгара, сугышта һәлак була. Медаль б-н бүләкләнә. Туган авылындагы мәчеткә А. исеме бирелә, укыган мәктәбенең диварына истәлек тактасы куела.

**АБДУРАХМА́НОВ** Адик Әскәр улы (16.01.1962, Чиләбе ш.), музыкант (флейта), дирижёр, педагог, РФнең атказ. артисты (1999). Ленинград (1987), Екатеринбург (1999) консерваторияләрен тәмамлый. 1984 елдан М.П.Мусоргский исем. Опера һәм балет театры оркестрында (Ленинград). 1987 дән Чиләбедә: М.И.Глинка исем. Опера һәм балет театры оркестрында эшли, музыка уч-щесендә укыта; 1992 дән мәдәният ин-тында, 2003 тән оркестр кыллы һәм тынлы музыка уен кораллары каф. мөдире; бер үк вакытта, 1994 тән, «Классика» филармония камера оркестрына нигез салучы һәм аның җитәкчесе. Чиләбе шәһәренең мактаулы гражданы (2017).

**АБЛА́ЕВ** Илдар Мансур улы (22.4.1954, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2006), проф. (2007). Казан ун-тын (1980), Нью-Йорк ун-тын (1994), Көнбатыш Онтарио ун-тының бизнес мәктәбен (1993, Канада) тәмамлый. 1980–88 елларда Казан ун-тының икътисад кафедрасында өлкән укытучы, доцент. 1996 дан Респ-ка сәнәгать өлкәсе җитәкче кадрларын яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү уку-тикшеренү үзәге (хәзер ТР МК каршындагы Татарстан идарә академиясе) директоры (ректоры). Хезмәтләре дәүләтнең икътисадка катнашы, Россия икътисадын үзгәртеп кору мәсьәләләренә карый.

**АБРО́СИМОВА** Марина Юрьевна (23.5.1962, Бөгелмә р-ны Карабаш штп), педиатр, мед. фән. д-ры (2005), проф. (2009). Ка-

зан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1985), 6 нчы балалар хастаханәсендә эшли (Казан). 1993 елдан ГИДУВның 1 нче педиатрия кафедрасында. 1995 тән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка гаиләне, ана һәм балалар сәламәтлеген саклау үзәгендә. 1996 дан Казан мед. ун-тының сәламәтлек саклауны оештыру кафедрасында, 1997 дән биомедэтика, мед. хокукы һәм мед. тарихы кафедрасында, каф. мөдире (2009 дан). Хезмәтләре сабыйлар үлемен кисәтү, яшьләр сәламәтлеген саклау, медицинаның төрле өлкәләрендә этика мәсьәләләренә карый.

**АДЕ́ЛШИН** Азат Билал улы (1.1.1937, Горький өлкәсенең Петряксы р-ны Чүнбәли а.), су чистарту технологиясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1998), проф. (1991), ТССРның атказ. уйлап табучысы (1991), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1994). Горький төзүче инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), «Татнефтепроводстрой» трестында (Казан) эшли. 1966 елдан Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, су тәэминаты һәм су китәрү каф. мөдире (1986 дан). Хезмәтләре пычрак суларны (ш.и. нефтьле суларны) чистарту процессларын модельләштерү һәм экологик саф эчә торган су булдыруга карый. А. җитәкчелегендә гидроциклоннар, махсус утыртмалы су тондыру аппаратлары кулланылган блок корылмалар (станцияләр) эшләнә (ТР һәм РФ пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). «Нефть-су» эмульсияләренең дисперс составын билгеләү методикасын тәкъдим итә. Уйлап табуга 87 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР ФАнең Х.М.Мөштәри исем. бүләге лауреаты. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының өч көмеш медале б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (1996).

**АЗИ́ЗОВА** Алия Камил кызы (21.6.1960, Үзбәкстан ССРның Бохара өлкәсе Гыйждуван ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). 1982–89 елларда һәм 2002 дән «Кварт» АҖдә: мастер, инженер-технолог, цех башлыгы урынбасары, цех, бүлек башлыгы, директор урынбасары, баш инженер (2005 тән). 1989–2002 дә Бохара өлкәсе пр-тиеләрендә эшли. Дәүләт бүләге яңа буын композицион материаллар — ТРда җитештерелгән эре тоннажлы полимерлар нигезендә булдырылган динамик термоэлопластларны эшләүдә һәм җитештерүне оештыруда катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**АЙМӘ́ТОВ** Рәмис Кыям улы (4.10.1968, Чүпрәле р-ны Мунчәли а.), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2019). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1992), «Мәгърифәт», «Шәһри Казан» г-талары редакцияләрендә эшли: хәбәрче, әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, җаваплы сәркатип. 1995–98 елларда ТР Язучылар берлеге рәисе ярдәмчесе, 1998–2004 тә — Ш.Камал музей-фатиры, 2004–13 тә Г.Тукай әдәби музее мөдире, 2013 тән ТР Язучылар берлеге рәисенең беренче урынбасары. Фәлсәфи тирәнлек, психологизм б-н сугарылган, шәхеснең рухи дөньясын, хис-кичерешләрен хәрәкәттә гәүдәләндергән «Шомырт салкыннары» (2000), «Айның аръягында» (2005), «Бозлы җилкәннәр» (2016; русчага тәрҗемәдә «Свобода в неволе», 2016), төрек телендә «Tuzaktaki ozgurluk» («Тозактагы ялкын», 2017, Әнкара), әзәрбайҗан телендә «Simsəklər goynunda» («Яшеннәр кочагында», 2018, Баку) шигъри җыентыклары, «Син минем җанымның яртысы» (нотасы б-н җыр текстлары, 2018) китабы авторы. Шигырьләре рус, инглиз, төрек, әзәрбайҗан, чуаш һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән. Әдәби тәрҗемә б-н шөгыльләнә, төрек әдәбияты классигы Орхан Вәлинең шигырьләрен тәрҗемә итеп, «Сезнең өчен» җыентыгына туплап чыгара (2017). М.Җәлил исемендәге Респ-ка бүләге лауреаты (2017).

**АЙНЕТДИ́НОВА** Ирина Наил кызы (1.11.1962), педагог, пед. фән. д-ры (2012), Казан пед. ин-тын (1985), Казан ун-тын (2003) тәмамлый. Казан ун-тының Халыкара мөнәсәбәтләр ин-тында эшли, социаль-гуманитар юнәлеш өчен чит телләр каф. профессоры. Хезмәтләре гомуми пед., пед. һәм мәгариф тарихы, һөнәри белем бирү теориясе һәм методикасы мәсьәләләренә карый.

**АЙНЕТДИ́НОВА** Лариса Мәхмүт кызы (16.8.1973, Сахалин өлкәсе Оха ш.), тарихчы, тарих фән. канд. (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1995). 1999 елдан ТР ФА Татар энциклопедиясе ин-тының тарих һәм иҗтимагый фикер бүлегендә, 2012 дән фән, мәгариф һәм мәдәният бүлеге мөдире. Бер үк вакытта, 2000–10 да, Казан технол. ин-тының гуманитар дисциплиналар кафедрасында укыта (2006 дан доцент), 2006 дан ТР ФАдә — ТР Президенты каршындагы ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе секретаре. Энциклопедия басмаларын әзерләүгә зур өлеш кертә. Хезмәтләре 19 йөз – 20 йөз башында Казан губернасындагы иҗтимагый-сәяси оешмалар, Татарстан тарихына карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**АЙТУГА́НОВА** Миләүшә Ләбиб кызы (5.4.1963, Казан), журналист, тарихчы, тарих фән. канд. (1996), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2013). Казан ун-тын тәмамлый (1987). 1986–98 елларда «Татарстан» радиосы мөхәррире һәм яшьләр программаларын алып баручы. 1998–2002 дә «Татарстан» ДТРКсының радиотапшырулар буенча ген. директоры урынбасары. 2002–16 да «Татарстан – Яңа Гасыр» ААҖ Телерадиокомпаниясенең ген. директоры урынбасары, баш продюсеры. 2016 дан Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең башкарма директоры. 2017 дән ТРның «Татаркино» дәүләт мәдәният учреждениесе директоры. Бер үк вакытта, 1990 нан, Казан ун-тында укыта, 2005 тән Казан мәдәният ин-ты профессоры, кино һәм телевидение режиссурасы каф. мөдире. РФ Журналистлар берлеге (1991), РФ Кинематографистлар берлеге әгъзасы (2015). Халыкара «Татар моңы» яшь башкаручылар конкурсының сәнгать җитәкчесе. Хезмәтләре телевидение һәм кинематография тарихына карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**АКМУ́ЛЛИН** Александр Иванович (10.4.1953, Тельман р-ны (хәзер Нурлат р-ны) Торнаяз а.), вет. хезмәтен оештыручы-икътисадчы, вет. фән. д-ры (2005), ТРның атказ. вет. табибе (2003). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), Самара өлкәсенең Кошки р-ны Киров исем. к-зда баш вет. табибы булып эшли (1975–80). 1980 елдан Казан вет. ин-тының (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) вет. хезмәтен оештыру һәм икътисад кафедрасында, менеджмент һәм информацион технологияләр каф. мөдире (2011 дән). Хезмәтләре базар мөнәсәбәтләренә күчеш шартларында вет. хезмәтен оештыру һәм вет. икътисадына карый.

**АКСЁНОВ** Игорь Борисович (13.8.1948, Казан), радиотехник, техник фән. д-ры (2006). Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң (1972), шунда ук эшли, Укыту-гыйльми үзәк башлыгы (1995–2004), Исәпләү үзәге җитәкчесе (2004 тән), бер үк вакытта, 2006 дан, микроэлектрон аппаратура конструкцияләү һәм җитештерү каф. мөдире. Хезмәтләре сигналларны дискрет-аналог алымы б-н эшкәртү һәм чуалчык динамикалы процессларны анализлауга карый. Аппарат диагностикасы өчен динамик процесс стационарлыгының интервалларын тиңләштерү алымын эшли. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**АКЧУ́РИН** Тимур Марат улы (28.5.1965, Казан), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1987), Татарстан җитештерү оешмаларында эшли. 2003 елдан ТР экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары. Дәүләт бүләге «ТР көнбатыш өлешенең нефтьле булуы перспективаларын ачыклау һәм нефть чыганакларын эзләү алымнары комплексын эшләү» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**АЛЕКСЕ́ЕВ** Андрей Георгиевич (17.10.1961, Казан), нейрохирург, мед. фән. канд. (2005), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), Казан шәһәрендәге мед. учреждениеләрендә: Ашыгыч мед. ярдәме күрсәтү хастаханәсендә, Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында, Респ-ка балалар клиник хастаханәсендә нейрохирург. 2005 елда Непалда эшли. 2006 да Берн нейрохирургия һәм нейрорадиология университет клиникасында (Швейцария), 2010 да Хельсинки нейрохирургия университет клиникасында (Финляндия) стажировка уза. 2006 дан Төбәкара клиник диагностика үзәгенең нейрохирургия бүлеге мөдире. Фәнни тикшеренүләре Үзәк нерв системасында метастазалы шешләр булган авыруларны комплекслы дәвалауга карый. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында баш мие кан әйләнеше кискен бозылган авыруларга медицина ярдәме күрсәтү» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**АЛЕКСЕ́ЕВА** Елена Петровна (3.3.1959, Уфа ш.), китап белгече, тарих фән. канд. (2004), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе

(2009). Бөтенсоюз кинематография ин-тын тәмамлый (ВГИК; Мәскәү, 1988). 1989–97 елларда ТР Кинематографистлар берлегендә иҗат комиссияләре консультанты, 1997–2008дә ТР ФА «Прометей» эксперименталь эстетика фәнни-тикшеренү ин-ты фәнни хезмәткәре. 2008дән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында, 2010 нан кино, видео иҗаты каф. мөдире. Казан кинохроника студиясендә төшерелгән «Зөя елгасы» («Свияга-река»), «Болгарлар» («Болгары»), «Алабуга» («Елабуга») док. фильмнарының сценарийлары авторы. Хезмәтләре Казан кинематографиясе тарихына карый.

**АЛИУ́ЛЛОВ** Рәшит Рәхимулла улы (2.8.1959, Чуаш АССР, Батыр р-ны, Озын Куак а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2004), проф. Чуаш ун-тын, СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясен тәмамлый. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик ин-тында адм. хокук, эчке эшләр органнарында адм. эшчәнлек һәм идарә каф. начальнигы, полиция полковнигы.

**А́ЛИШЕВ** Булат Сәлам улы (14.5.1954, Лаеш р-ны Татар Сараланы а.), психолог, психол. фән. д-ры (2002), проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1978 елдан Һөнәри белем бирү пед. һәм психол. ин-тында, һөнәри белем бирү психологиясе лаб-ясе мөдире. Бер үк вакытта Казан ун-тында эшли, 2008–11 дә психол. ф-ты деканы, 2009 дан ун-тның Чаллы ф-лында. Хезмәтләре кече төркемнәр һәм коллективларның социаль психологиясенә, шәхес психологиясенә карый. «Төп һөнәри белем бирүне психологик тәэмин итү» хезмәтләр циклы өчен РФ Хөкүмәте бүләгенә лаек була (2007). РФнең мактаулы урта һөнәри белем бирү хезмәткәре (2005).

**АЛСУ́** (псевд., Сафина, кияүгә чыкканнан соң Абрамова Алсу Ралиф кызы) (27.6.1983, Бөгелмә ш.), җырчы, ТРның халык артисты (2010), РФнең атказ. артисты (2018). Рус, инглиз, татар телләрендә җырлый. Күп кенә җырларның текстларын һәм музыкасын үзе иҗат итә. А. башкаруында популярлашкан җырлар: «Зимний сон», «Весна», «Иногда», «Before you love me», «Осень», «Всё равно», «Әткәй», «You’re my number one» (Э.Иглесиас б-н дуэт), «Angel», «Complete», «Everybody», «Там, где рождается свет» һ.б. Альбомнары (дисклар): «Алсу» («Alsou»), «Мне приснилась осень», «Always on my mind», «19», «Самое главное», «Туган тел» һ.б. Концерт программалары: «Трилогия», «Алсу и её авторы», «Solo», «Летящая над облаками» һ.б. Фильмнарга җырлар яздыра. А. хезмәттәшлек иткән продюсерлар, җырлар авторлары, куючылар — В.Белоцерковский, А.Шевченко, Ю.Грымов, В.Байков, Э.Лэйн, П.Смит. «Евроведение» (2 нче урын, Швеция, 2000), елның иң популяр Россия артисты буларак, «World Music Awards» (Монако, 2001) һәм MTV «Europe Music Awards-2001» (Германия), МУЗ-ТВ («Елның иң яхшы башкаручысы», Россия, 2003) бүләкләре лауреаты. Бөгелмә шәһәренең мактаулы гражданы (2000).

**А́ЛТЫКИС** Михаил Григорьевич (21.9.1939, Ростов-Дон ш. — 15.2.2005, Казан), төзелеш материаллары гыйлеме өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2004). Казан төзүче инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) тәмамлый (1961), 1973–2005 елларда шунда ук эшли, төзелеш материаллары каф. профессоры. (1998 дән). 1962–64 тә «Казтрансстрой» трестының төзелеш идарәсендә, 1964–66 да Казан ун-тында, 1967–73 тә Тимер конструкцияләр һәм бетон фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан), бүлек мөдире (1970–73). Хезмәтләре төзелеш материалларының һәм конструкцияләренең озак вакыт файдаланылу ныклыгын өйрәнүгә һәм фаразлауга карый. Төрле кулланыштагы үзле гипслы матдәләр булдыру өчен составлар һәм технологияләр эшли. Структур гипс үзгәрешләре механизмын тикшерә, төзелеш материаллары составын һәм структурасын көйләү ысулларын тәкъдим итә. Уйлап табуга 36 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медаль б-н бүләкләнә.

**АЛТЫНБА́ЕВ** Рәшит Әсхәт улы (3.8.1960, Куйбышев ш.), невропатолог, мед. фән. д-ры (2002). Куйбышев мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), Чаллыдагы дәвалау учреждениеләрендә эшли. 1988 елдан Казанда: 20 нче поликлиниканың баш табиб урынбасары; 18 нче шәһәр хастаханәсендә: поликлиниканың баш табиб урынбасары, 1991 дән неврология бүлеге мөдире. 1992 дән Казан мед. ун-тының неврология кафедрасында. Хезмәтләре умыртка сөяге каналларын компьютер-томография ысулы б-н тикшерүгә, вертеброген бил-оча сөяге нерв җепселләре бәйләме синдромы формалашу закончалыкларын өйрәнүгә, умыртка сөяге дистрофиясен профилактикалауга һәм дәвалауга карый.

**АЛУ́Ф** Мария Александровна (26.1.1901, Кострома ш. – 6.11.1964, Казан), фармаколог, мед. фән. д-ры (1936). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1925), шунда ук фармакол. кафедрасында эшли. 1936–39, 1941–58 елларда Казан мед. ин-тының фармакол. каф. мөдире, 1936–48 дә Стомат. ин-тының стомат. каф. мөдире. Хезмәтләре үсемлек һәм синтетик дару чыганакларын өйрәнүгә карый. Аның тарафыннан глаукоманы дәвалау өчен «Армин» препараты эшләнә. А. — «Дару үләннәре турында белешмәлек» («Справочник по лекарственным травам», М., 1943) төзүчеләрнең берсе. Медаль б-н бүләкләнә.

**АЛЫ́КОВ** Марат Равил улы (20.8.1959, Әстерхан өлкәсенең Актүбә р-ны Капустин Яр пос.), РФ Герое (31.5.1998), майор, РФнең атказ. очучы сынаучысы (2003), икътисад фән. канд. (2003). Качинск югары хәрби очучылар уч-щесен (1980), РФ Президенты каршындагы Россия дәүләт хезмәте академиясен (2006, Мәскәү) тәмамлый. 1976 елдан Совет Армиясендә, СССР Хәрби Һава Көчләренең строевой частьларында хезмәт итә. Совет гаскәрләренең Әфганстан Респ-касындагы чикләнгән контингентының авиация частьлары составында Су-17М3 истребитель-бомбардировщигында 214 сугышчан очыш ясый. 1985 тән запаста. 1987–2005 тә А.И.Микоян исем. тәҗрибә КБда (Мәскәү) сынау очышлары эшендә. А. тавыш тизлегеннән югары МиГ-29СМ истребителенә сынау үткәрә, МиГ-29, МиГ-29СМТ, МиГ-29УБТ, МиГ-29М2, МиГ-31, МиГ-АТ самолётларын сынауда катнаша. Герой исеме яңа авиация техникасын сынау вакытында күрсәткән батырлыклары өчен бирелә. 2006 дан Мәскәү өлкәсендәге Жуковский шәһәрендә яши. Кызыл Йолдыз, «Шәхси батырлык өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**АНА́ШКИН** Владимир Николаевич (8.8.1955, Казан), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли. Хезмәтләре төш квадруполь резонансы, томографиягә карый. Дәүләт бүләге «ТМР-0,06-КФТИ» мед. магнит-резонанслы томографын эшләүдә, ясауда һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**АНДРЕ́ЕВА** Юлия Валентиновна (30.10.1970, Казан), педагог, психолог, пед. фән. д-ры (2007). 1992 елда Казан ун-тының журналистика һәм социол. ф-тын тәмамлый. 2001 дән Казан ун-тының Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбендә укыта, телепроизводство һәм цифрлы коммуникацияләр каф. профессоры (2013). Хезмәтләре көндәшлеккә сәләтле журналистлар әзерләү мәсьәләләренә карый.

**АНДРИА́Н** (Александр Геннадьевич Четвергов) (14.2.1951, Казан – 10.8.2005, Киров өлкәсе, Мәскәүдә җирләнә), дин эшлеклесе. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1974). 1986 елдан Казан Мәрьям Ана иконасы храмы каршындагы Казан иске дин тарафдарлары общинасында, 1992–96 да — рәис. 1999 дан дьякон, 2000 нән изге иерей, 2001 дән монахлыкта. 2001–03 тә Казан-Вятка епархиясендә епископ, 2004 тән Рус православие иске дин тарафдарлары чиркәвенең Мәскәү һәм Бөтенрусь митрополиты. Иске дин тарафдарлары чиркәве б-н Рус православие чиркәве арасында мөнәсәбәтне җайга салуга көч куя; проф. дәрәҗәдә икона язу б-н шөгыльләнә.

**АНДРОНЕ́НКО** Сергей Иванович (3.7.1950, Эстония ССР, Таллин ш.), радиофизик, физика-матем. фән. д-ры (2013). Ленинград ун-тын тәмамлый (1973). 1973–76 елларда «Вектор» ФҖБдә программалаучы инженер (Ленинград). 1976–98 дә СССР ФАнең (1991 дән РФАнең) Силикатлар химиясе ин-тында: өлкән инженер, кече фәнни хезмәткәр, фәнни хезмәткәр, өлкән фәнни хезмәткәр. 1994–95, 1998–2004, 2004–08, 2014–15 тә (бүленеп) Монреаль шәһәренең Конкордия ун-тында эшли (Канада). 2011 дән (бүленеп) Казан ун-тының Физика ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр. Халыкара ЭПР җәмгыяте (International EPR Society) әгъзасы (1995 тән), Халыкара «Communication Chemistry», «Industrial and Engineering Chemistry Research», «Diamond and related materials», «Inorganic Chemistry», «Molecular Physics», «Material science in semiconductor processing», «Magnetic Resonance in Solids» ж-лларында рецензент (2014 тән). АКШ,

Һиндстан, Канада һәм башка чит илләрдәге фәнни үзәкләр б-н хезмәттәшлек итә. Каты җисем физикасына, ТМР һәм ЭПР спектроскопиясенә багышланган күпсанлы бөтенсоюз, бөтенроссия һәм халыкара симпозиумнарда һәм конференцияләрдә катнаша. Хезмәтләре кушылма ионнарның монокристалларда, пыялаларда һәм наноструктуралашкан керамикаларда электрон парамагнит резонансы өлкәсендәге эксперименталь һәм теоретик тикшеренүләр даирәсенә карый. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

**АНИКЕЕ́НОК** Олег Алексеевич (1.3.1949, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (2015). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), Казан оптика-механика з-дында (КОМЗ), 1981 елдан Казан физика-техника ин-тында (КФТИ) эшли. 1989 дан Казан ун-тының физика ф-тында, 1998 дән Казан ун-тының Яшел Үзән ф-лы физика ф-тында, 2014–19 да ун-тның теоретик физика кафедрасында. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре каты җисем теориясенә: нәортогональ базислы икенчел квантлау ысулына; ионара бәйләнешле кристалларның локальләшкән халәттә тайпылыш теориясенә; леганд дәрәҗәсендәге супернечкә тәэсир итешүләргә; ионлашкан кристалларда ерактан кулон тәэсир итешүләренә карый.

**АНО́ХИНА** Антонина Васильевна (15.6.1957, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (2004), проф. (2009). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1979). 1980 елдан 4 нче стомат. поликлиникасында эшли (Казан). 1987 дән Казан мед. академиясендә, проректор (2008 дән), терапевтик һәм балалар стоматологиясе һәм ортодонтиясе каф. мөдире (2012 дән). Хезмәтләре балалар стоматологиясенә карый.

**АНТИ́ПОВ** Альберт Иванович (22.3.1942, БАССРның Шаран р-ны Базгыя а. – 6.8.2014, Әлмәт ш.), җылылык техникасы инженеры, техник фән. д-ры (2007), проф. (2008). Ленинград технол. ин-тын тәмамлый (1964). 1959–61 елларда Киров з-дының (Ленинград) монтажлау участогында слесарь, 1966–73 тә «Башоргэнергонефть» монтажлау-көйләү идарәсенең җылылык техникасы участогында техник, инженер булып эшли. 1966–73 тә «Татнефть» берләшмәсе (Әлмәт ш.) үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясенең энергия ресурсларын тикшерү бүлеге башлыгы, 1973–92 дә Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тының Татарстан кичке ф-тында (Әлмәт ш.) укытучы, өлкән укытучы, доцент, 1992–2014 тә Әлмәт дәүләт нефть ин-тында доцент, проф., сәнәгать җылылык энергетикасы каф. мөдире. Хезмәтләре гидромеханика, җылылык техникасы, нефть сәнәгате объектларында җылылык энергетикасы ресурсларын нәтиҗәле файдалану мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга патентлы бар.

**АНТИ́ПОВ** Михаил Андреевич (31.7.1961, Лениногорск ш.), геофизик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Мәскәү нефть һәм газ ин-тын тәмамлый (1987). 1978–2004 елларда «Татнефтегеофизика» АҖдә эшли: слесарь-электромонтажчы, инженер-оператор, газ каротажы партиясе отряды башлыгы, Лениногорск промысел-геофизик конторасы инженеры; тәҗрибә-җитештерү экспедициясе инженеры, фәнни-техник идарә күчмә отряды башлыгы, «ТНГ – Көнбатыш Казакъстан» ф-лында инженер-геолог. 2004 тән «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖнең әйдәп баручы инженеры, проект-конструкцияләү бүлеге башлыгы урынбасары, баш энергетик бүлеге башлыгы урынбасары. Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касының энергетика куркынычсызлыгын ныгыту эшендә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**АНТО́НОВ** Александр Валентинович (1.1.1957, Грузия ССР, Кутаиси ш. – 17.11.2013, Казан), генерал-майор (2010). Мәскәү ун-тын (1980), Курск дәүләт, муниципаль идарә ин-тын (2003) тәмамлый. 1984 елдан Липецк шәһәрендә дәүләт иминлеге органнарында. 2009–11 дә Федераль иминлек хезмәтенең Коми Респ-касы, 2011 дән ТР буенча Идарәләре башлыгы. Медальләр б-н бүләкләнә.

**АНТО́НОВ** Геннадий Петрович (30.8.1949, Чуаш АССРның Киря пос.), геофизик, техник фән. канд. (1992), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1992). Казан у-тын тәмамлаганнан соң (1979), ТатНИПИнефтьтә (Бөгелмә ш.) эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1993 елдан), радиацион һәм сәнәгый куркынычсызлык лаб-ясе мөдире (1998 дән), радиацион куркынычсызлык секторы мөдире (2002 дән), нефть чыганакларын эшкәрткәндә экологик куркынычсызлык саклау бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре (2007 дән). 2009 дан «Наука» ҖЧҖнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре (Бөгелмә). Дәүләт бүләге гидрогеологиядә һәм Татарстан нефть чыганакларын эшкәртүгә контрольлек итү максатында индикатор тикшеренүләрнең аппаратура-методик комплексын булдыруда һәм киң күләмдә гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**АРХИ́ПОВА** Наталия Николаевна (13.4.1953, Казан – 29.5.2012, шунда ук), педиатр, мед. фән. д-ры (2006). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1976), Казан мед. академиясенең 1 нче педиатрия кафедрасында эшли. Хезмәтләре балалар сәламәтлеге торышын ачыклау методикаларын һәм рахит, рахитка охшаш авырулар б-н авыручыларны сәламәтләндерү чараларын эшләүгә карый.

**АСА́НОВ** Әсхәт Җәмил улы (10.1.1949, Азнакай пос.), математик, техник фән. д-ры (2005), проф. (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1972), Мари машиналар төзү з-дында (Йошкар-Ола ш.) эшли. 1980 елдан Чаллыда: Кама политехник ин-тында (хәзер Кама инженерлык-икътисад академиясе), 2006 дан Казан ун-ты ф-лында, гамәли матем. һәм информатика каф. мөдире (2012 дән). Хезмәтләре системалы анализ, матем. идарә теориясенә карый. Системаларны кертү технологияләре нигезендә катлаулы динамик объектлар б-н күп үлчәмле адаптив идарә итү системаларын аналитик синтезлау теориясен тәкъдим итә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2007).

**АСЛӘ́МОВ** Илдар Равил улы (4.8.1978, Зәй ш.), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). Казан технол. ун-тын тәмамлый (2001). Идел углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. Хезмәтләре углеводород чималын күкертле кушылмалардан чистарту технологиясен эшләүгә карый. Дәүләт бүләге углеводород чималын чистарту өчен фталоцианинлы катализаторлар эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**АСТА́ФЬЕВ** Владимир Васильевич (19.8.1952, Чуаш АССРның Ибреси р-ны Ибреси пос.), тарихчы, тарих фән. канд. (1984), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1982–84 елларда «Ленинец» г-тасы мөхәррире (Казан). 1985 тән Казан ун-тында фәнни-пед. эштә, 1998–2004 тә историография һәм чыганакларны өйрәнү каф. мөдире, 2005–11 дә тарих ф-ты деканы урынбасары, 2011–13 тә Тарих ин-тының тарих бүлеге мөдире. Хезмәтләре Казан ун-ты тарихына, биографикага (Г.В.Плеханов, Н.П.Загоскин һ.б.) карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**АСТА́ЩЕНКО** Владимир Иванович (28.9.1952, Брянск өлкәсенең Погар р-ны Андрейковичи а.), материаллар гыйлеме өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2008). Себер металлургия ин-тын (Кемерово өлкәсе, Новокузнецк ш.) тәмамлаганнан соң (1974), КамАЗда эшли, Лаборатор-тикшеренү эшләре идарәсенең химик-термик эшкәртү лаб-ясе башлыгы (1978–86). 1987 дән Кама инженерлык-икътисад академиясендә, машиналар һәм кою технологиясе каф. профессоры (2008 дән). Хезмәтләре яңа материаллар эшләү, металл эшләнмәләрне термик һәм ныгытулы эшкәртү, авыр йөк машиналары детальләренең сыйфатын һәм ышанычлылыгын арттыруга карый. Уйлап табуга 22 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә. СССРның уйлап табучысы (1986), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2012).

**АТНА́ШЕВ** Әхәт Мәхмүт улы (12.12.1917, хәзер Казакъстан Респ-касының Төньяк Казакъстан өлкәсе Петропавловск ш. – 25.8.1944, Берлин), совет хәрби әсирләренең яшерен антифашистик оешмасы (Җәлил–Кормаш төркеме) әгъзасы. Хисапчылар курсларында укый. 1938 елдан Кызыл Армиядә. Пулемёт расчёты командиры, кече политрук. Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә (1942). 1942 нең җәендә әсирлеккә эләгә. Хәрби әсирләр лагерьларында «Идел-Урал» легионына керә, 827 нче батальон командиры була, батальонны партизаннар ягына чыгарга әзерли. Яшерен оешма фаш ителгәннән соң (1943), аның 10 әгъзасы б-н бергә үлемгә хөкем ителә һәм 1944 елның 25 августында Плётцензее төрмәсендә җәзалап үтерелә (Берлин, Германия). СССР Президенты М.С.Горбачёвның 1990 ел 5 май Указы нигезендә, яшерен антифашистик төркемдә алып барган патриотик эшчәнлеге, ныклыгы һәм батырлыгы өчен, үлгәннән соң 1 нче

дәрәҗә Ватан сугышы ордены б-н бүләкләнә. А. һәм яшерен оешманың аның б-н бергә җәзага дучар ителгән башка әгъзаларының каһарманлыгы Казан Кремле каршындагы 1 Май мәйданына урнаштырылган мемориаль комплекста мәңгеләштерелә.

**АФАНА́СЬЕВ** Вадим Владимирович (23.8.1952, Украина ССР, Кировоград ш.), радиоэлектроника һәм телекоммуникация өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2004), проф. (2006). 1975 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, радиэлектрон һәм квант җайланмалары каф. профессоры (2004 тән). Хезмәтләре даими һәм хаотик динамикалы сызыкча булмаган системага карый. Стационар булмаган очраклы фракталь процессларны һәм сигналларны өйрәнә. Гомумиләштерелгән спектраль анализ һәм фракталь процессларны режекторлау алымын, сызыкча булмаган радио-, оптик-электрон һәм квант җайланмаларын һәм динамик хаослы системаларны анализлау, диагностикалау, стабильләштерү һәм идарә итүнең сыйфатлы ысулларын эшли. А.ның эшләнмәләре борт системаларындагы очкыч аппаратларның двигательләрен һәм узелларын контрольдә тотуда файдаланыла. Уйлап табуда 19 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медаль белән бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2007).

**АФАНА́СЬЕВА** Зинаида Александровна (3.12.1956, Апас р-ны Бушанчы а.), онколог, эндокринолог, мед. фән. д-ры (2006). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1980). 1981 елдан Минзәлә Үзәк район хастаханәсендә хирург, 1984 тән хирургия бүлеге мөдире, 1987 дән Яшел Үзән Үзәк район хастаханәсендә эшли. 1985–89 да һәм 2010 нан Казан мед. академиясенең онкология һәм хирургия кафедрасында, каф. профессоры (2010 нан). 1989–2001 дә Казан онкология диспансерендә, 2002–10 да ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Калкансыман биздә яман шеш булган авыруларга диагноз кую һәм авыруны дәвалау үзәге мөдире. Хезмәтләре калкансыман биз рагы очракларында комплекслы диагноз кую һәм авыруны дәвалауга карый. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

**АФЗА́ЛОВ** Фоат Зыятдин улы (3.8.1948, Азнакай р-ны Яхшыбай а.), вет. патологоанатомы, вет. фән. д-ры (2002), ТРның атказ. вет. табибе (2000). Казан. вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнан соң (1971), шунда ук патологик анатомия кафедрасында эшли, проф. (2009 дан). Хезмәтләре а.х. терлекләрендә хламидиоз, түләмә, туберкулёз, бруцеллёз авырулары патоморфологиясе, патогенезы һәм иммуноморфологиясенә карый.

**АЮХА́НОВ** Закир Насыйр улы (23.5.1889, Сембер губ. Татар Калмаюры а. — 22.6.1961, Уфа) дин белгече, тел галиме, педагог. «Хөсәения» (Оренбург ш., 1910), мәдрәсәсен, «әл-Әзһар» (Каһирә, 1914), Томск (1926) ун-тларын тәмамлый. 1914–16 елларда «Хөсәения» мәдрәсәсендә тарих, гарәп, төрек, татар телләре укыта, яңача пед. карашлары өчен попечительләр тарафыннан тәнкыйтьләнә. 1916–17 дә «Галия» (Уфа ш.) мәдрәсәсендә, 1918–26 да Томск шәһәрендәге Себер татар укытучылар семинариясендә, татар пед. техникумында һ.б. уку йортларында укыта. 1926–36 да Уфада: В.И.Ленин исем. Респ-ка ятим балалар мәктәбендә уку бүлеге мөдире, укытучы, 1930–36 да а.х. һәм пед. ин-тларында доцент. 1936 да Мәскәүдә 523 нче татар мәктәбендә, 1937–56 да Уфаның 14 нче мәктәбендә укытучы. 1959–61 дә СССР ФА Башкортстан ф-лының Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында фәнни хезмәткәр, Башкорт дәүләт ун-тында гарәп теле укытучысы. Башлангыч хезмәтләре Ислам тарихы, дини-хокукый мәктәпләрне тасвирлау, мөселман хокукы, салым, зәкят һәм рибачылык мәсьәләләренә карый. Төрки шәҗәрләрне өйрәнә. Башкорт әлифбасын әзерләүдә, башкорт мәктәпләре өчен дәреслекләр һәм уку-укыту–методик ярдәмлекләр төзүдә катнаша. Популяр «Әлифба» авторы (1930; 25 басма, 1947).

**ӘБҖӘЛИ́ЛОВ** Дамир Фәрид улы (6.10.1973, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2009). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1995), шунда ук гомуми матем. кафедрасында, бер үк вакытта, 1998–2007 дә, Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. Хезмәтләре сыеклык һәм газ механикасының кире кырый мәсьәләләренә карый. Очучан аппаратларның канат профильләрен аэродинамик проектлау алымнарын эшли, тышкы агымны аерып алу җайланмаларын куллану һәм реактив агынтыны өрдереп чыгару шартларында күтәрмә көченең (Су) югары коэффициентларына ирешү мөмкинлеген күрсәтә, мондый профильле контурларның оптималь формаларын билгели. Кайбер катлаулы агым схемаларында ягалап агуга дучар җисемнәрдә Су ның югары бәяләмәләрен ачыклый.

**ӘБҖӘЛИ́ЛОВА** Ләйсән Рәхим кызы (18.11.1979, Казан), икътисадчы, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), икътисад фән. канд. (2006). Казан химия-технол. ун-тын тәмамлаганнан соң (2002), «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖдә эшли: әйдәп баручы белгеч, икътисади анализ бүлеге башлыгы, 2010 елдан ген. директор урынбасары. Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касы нефть-газ химиясе комплексының 1999–2003 һәм 2004–08 елларга үсеш программасының фәнни нигезләрен әзерләүдә һәм программаны гамәлгә ашыруда катнашканы өчен бирелә.

**ӘБҖӘЛИ́МОВ** Рәис Шакир улы (1.7.1938, Саратов өлкәсенең Дергачи р-ны Алтата а.), төзүче-инженер, техник фән. д-ры (2007), РФнең атказ. төзүчесе (1996). Себер автомобиль-юл ин-тын (Омск) тәмамлаганнан соң (1967), Омск шәһәрендә: төзелеш оешмаларында һәм ясалма каучук з-дында эшли (1958–74); 1974 елдан «Омскгражданпроект» АҖдә, ген. директор киңәшчесе (2004 тән). Хезмәтләре нигезләрне аерым шартларда проектлауга карый. Ә. сезонлы туңа торган грунтларның бина фундаментлары һәм җир асты корылмалары б-н үзара тәэсир итү кочен өйрәнә. Грунтның чагыштырма деформация зурлыгының басымнан бәйлелеген билгели торган җайланма һәм ысул эшли.

**ӘБҖӘЛИ́МОВ** Эдуард Марат улы (9.3.1984, Чиләбе өлкәсенең Миасс ш.), спортчы (бокс), Россиянең атказ. спорт остасы (2010). Урал физик культура академиясен тәмамлый (2008). Яшүсмерләр арасында Европа (2001), дөнья (2002) чемпионатлары, Россия чемпионаты (2008 — алтын, 2003, 2005 — көмеш, 2011 — бронза), Дөнья кубогы (2005), дөнья чемпионаты (2009 — көмеш), Европа чемпионаты (2010) җиңүчесе һәм призёры.

**ӘБУ́СЕВ** Рәкыйп Әхмәт улы (14.1.1939, Оренбург өлкәсенең Таш Имангол а. – 17.1.2005, Пермь ш.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1995). Пермь ун-тын тәмамлаганнан соң (1967), шунда ук эшли, ихтималлыклар теориясе һәм матем. стат. каф. мөдире (1996). Хезмәтләре матем. стат., күп үлчәнешле стат. анализ, үлчәнешлекне киметү һәм классификацияләүгә карый. Күп үлчәнешле параметрик семьялыкларның җитәрлек статистикасын бүлеп кую өчен күчерелмәгән һәм Байес бәяләмәләрен төзи, төркем классификациясенең асимптотик оптималь хәлиткеч кагыйдәләрен эшли.

**ӘДҺӘ́МОВ** Наил Рашат улы (20.3.1958, Үзбәкстан ССР, Ташкент), а.х.н механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2007). Ташкент а.х.н ирригацияләү һәм механикалаштыру инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), шунда ук эшли (бүленеп: 1980–82 елларда Ташкент техник фәнни-тикшеренү ин-тында. 1998 дән Казан аграр ун-тында, техник сервис каф. мөдире (2006 дан). Хезмәтләре а.х. машиналарының технол. ышанычлылыгын арттыруга карый. Урып-җыю машиналары эш органнарының тизлек параметрларын, тоткарсызлык эшләү шартларын һәм хәрәкәтчән узелларының тузуга чыдамлыгын тикшерә. Тузган детальләрне пластик деформацияләү һәм плазмалы металлаштыру алымнары б-н торгызу ысулларын тәкъдим итә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**ӘКБӘ́РОВА** Фирая Бари кызы (2.6.1952, Югары Ослан р-ны Кызыл Байрак а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2012). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1974), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Театр сәхнәсендә эчкерсез яшь кызлар образларын гәүдәләндерә: Катя («Мәскәү каникуллары», А.И. Кузнецов), Лёлька («Бер төн», Б.Л.Горбатов), Дүрткүз («Авыл эте Акбай», Т.Миңнуллин) һ.б., соңрак тормышчан, характерлы рольләр башкаруга күчә: Үлмәс («Боз астында дулкын», Ә.-Т.Рахманкулов), Гөлфия, Әүдәки («Дуслар җыелган җирдә», «Гөргөри кияүләре», Т.Миңнуллин), Фатыйма («Талак, талак», Х.Вахит), Сафура («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт), Хәдичә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Акулина Ивановна («Мещаннар», М.Горький), Тартюф («Тартюф», Ж.-Б.Мольер), Миңлесорур («Әтәч менгән читәнгә», А.Гыйләҗев), Әнисә («Исәнмесез?!», М.Гыйләҗев). Нәфис фильмнарда төшә.

**ӘКРА́МОВ** Наил Рамил улы (5.3.1973, Уфа ш.), балалар уролог-андрологы, мед. фән. д-ры (2008). Казан мед. ун-тын тәмамлый (1997). 1998 елдан Респ-ка балалар клиник хастаханәсендә эшли. Бер үк вакытта, 2002 дән, балалар хирургиясе кафедрасында, 2011 дән Казан. мед. ун-тының квалификация күтәрү һәм белгечләрне яңадан әзерләү ф-ты деканы. Хезмәтләре балаларның (ш.и. варикоцеле синдромы булган малайларның) бәвел системасында яман шеш барлыкка килүне ачыклауга карый. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш эксперты, балалар баш урологы (2006). Уйлап табуга 4 патенты бар.

**ӘМИ́НОВ** Камил Линар улы (12.4.1964, Казан), физик, физика-матем. фән. канд. (1991), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1985), шунда ук эшли. 1990 елдан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында. Хезмәтләре матем. теорияне үстерү, ЯМР һәм ЭПР өлкәсендәге тәҗрибәви тикшерүләр өчен яңа алгоритмнар, программа җәһәтендә тәэмин итү системасын эшләүгә карый. Дәүләт бүләге «ТМР-0,06-КФТИ» мед. магнит-резонанслы томографын эшләүдә, ясауда һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ӘМИ́НОВА** Венера Рудәл кызы (27.8.1966, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1988), шунда ук эшли, 2012 елдан әдәбият теориясе һәм компаративистика каф. мөдире. Хезмәтләре әдәбият теориясенә, әдәбият белеме компаративистикасына, 19 йөз рус әдәбиятына, 20 йөзнең 1 нче яртысы татар әдәбиятына карый.

**ӘМИ́НОВА** Зөлфә Мидхәт кызы (5.3.1955, Казан), кардиолог, рефлексотерапевт, мед. фән. д-ры (2003). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Норлат-Октябрь р-ны үзәк хастаханәсендә, Норлат шикәр з-дының сәламәтлек саклау пункты мөдире. 1993 елдан — ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Мөмкинлекләре чикле балалар һәм үсмерләрне тернәкләндерү үзәге, 2012 дән «Яңа медицина технологияләре» клиникасы (Казан) директоры. Хезмәтләре балаларны тернәкләндерү мәсьәләләренә карый, церебраль параличлы инвалид балаларны комплекслы мед.-психосоциаль тернәкләндерүне фәнни нигезли.

**ӘМИ́НОВА** (ире фамилиясе буенча Габдрахманова) Сәлимә Салават кызы (19.9.1969, Уфа ш.), хореограф, балетмейстер, режиссёр. ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2007). Казан сәнгать һәм мәдәният ин-тын тәмамлый (1993). 1992 елдан Татар акад. театрында балетмейстер. «Җанкисәккәем», «Гөргөри кияүләре», «Диләфрүз-Remake», «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин), «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), «Галиябану» (М.Фәйзи), «Банкрот» (Г.Камал), «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт), «Мәңгелек буран» (Ч.Айтматов), «Бармы ришвәттән дәва?..» (З.Хәким) һ.б. спектакльләрнең балетмейстеры. «Казан егетләре» (М.Гыйләҗев), «Кыю кызлар» (Т.Гыйззәт), «Җан Баевич» (Г.Исхакый), «Ханума» (А.Цагарели) һ.б. спектакльләрнең хореографы. «Кәҗә, Сарык һ.б.» (И.Зәйниев), «Derdmend» (З.Рәмиев) спектакльләренең режиссёры. Г. ш.у. аерым концерт номерлары да куя.

**ӘМИ́РОВ** Марат Фоат улы (10.12.1956, Ульянов өлкәсенең Иске Кулатка эшчеләр пос.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2007), проф. (2007). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), Ульянов өлкәсе Иске Кулатка р-нының Тельман исем. к-зында баш агроном булып эшли. 1987 елдан Казан а.х. ин-тында (хәзер Казан аграр ун-ты), үсемлекләрне өйрәнү каф. мөдире (2006 дан), уку-укыту һәм методика идарәсе башлыгы (2007). Хезмәтләре бөртекле сабан бодае игү ысулларына һәм Идел буеның урман-далалы төньяк районнарында аның чәчү мәйданнарын киңәйтү мөмкинлекләрен булдыруга карый.

**ӘМИ́РОВ** Рөстәм Рафаэль улы (21.9.1958, ГДР, Потсдам ш.), химик, химия фән. д-ры (2007). 1980 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, нәорганик химия каф. профессоры. (2007 дән). Хезмәтләре фосфорорганик комплекслар һәм азотлы лигандалар б-н берлектә күчешле металлар комплексларын тикшерү, оешкан матдәләрдә өслекчә-актив матдәләрнең су эремәләре һәм макроцикллар нигезендә металл комплекслары барлыкка килүне өйрәнүгә, яңа металлы полимерлар булдыруга һәм аларның үзлекләрен ачыклауга карый. Уйлап табуга 3 патенты бар.

**ӘМИ́РОВА** Лилия Миңнеәхмәд кызы (23.3.1958, Октябрь р-ны Нурлат штп), химик-органик, химия фән. д-ры (2004), проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1980), Бөтенсоюз ясалма каучук фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында, Казан ун-тында (1981 елдан), Казан төзүче инженерлар ин-тында (1986 дан) эшли. 1989 дан Казан техник ун-тында, бер үк вакытта, 2005 тән, Казан технол. ун-ты «Союзхимпромпроект» проект ин-тының технол. бүлеге башлыгы. Хезмәтләре полимерлар һәм полимер композицион материаллар синтезына карый. Төзелештә, медицинада, арматуралы пластиклар җитештерүдә куллану өчен бәйләгечләр тәкъдим итә, оптикада һәм квант электроникасында кулланылган полимерлар (состав һәм үзлекләрне киселеш күрсәткече буенча тарату градиентын кулланып) һәм полимер материаллар (фосфорлы к-таның глицидил эфирлары нигезендә ясалган полимерларга металлар ионнарын кертеп) синтезы алымнарын эшли. Уйлап табуга 19 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘМИРХА́НОВ** Марат Инкыйлап улы (2.5.1971, Бөгелмә ш.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010), техник фән. канд. (2008). Мәскәү нефть һәм газ академиясен тәмамлый (1993), ТатНИПИнефтьтә (Бөгелмә) эшли, нефть җыю секторы мөдире (2001–03), суландырылган катламнардан нефть алуны арттыру бүлеге башлыгы (2013 тән). Хезмәтләре нефть алуны интенсивлаштыру өлкәсенә карый. Дәүләт бүләге промыселдан нефть ташуның ышанычлылыгын арттыру буенча технол. алымнар комплексын тикшерү һәм сәнәгый гамәлгә ашыруда катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 60 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**ӘСРЕТДИ́НОВА** Резилә Әхмәт кызы (5.11.1960, Арча р-ны Сеже а.), вет. табибе, вет. фән. д-ры (2010). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), Мари АССР Кужener вет. станциясе башлыгы урынбасары булып эшли. 1986–94 елларда Бөтенсоюз вет. фәнни-тикшеренү ин-тында. 1994 тән Казан вет. медицинасы академиясендә, зоогигиена каф. профессоры (2012 дән). Хезмәтләре яшь терлекләрнең специфик булмаган резистентлыгын, аларны үстерү һәм тәрбияләү шартларын, препаратларның фармакологик һәм токсикологик сыйфатларын һәм аларны ветеринариядә нәтиҗәле иммунотроп чаралар буларак куллануны өйрәнүгә карый.

**ӘСФӘНДИЯ́РОВА** Җәмилә Ефим кызы (3.1.1969, Казан), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2008). Казан театр уч-щесен (1988), Икътисад, идарә һәм хокук ин-тын (Казан, 2005) тәмамлый. 1988 елдан Казан Яшь тамашачылар театрында, 1989 дан Татар драма һәм комедия театрында, бер үк вакытта, 2006 дан, Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тында укыта. Киң планлы актриса, драматик, комедиячел, характерлы рольләрне ышандырырлык итеп башкара. Героиняларының эчке дөньяларын тирәнтен һәм төрле яклап ача. Аеруча зур рольләре: Василиса («Тормыш төбендә», М.Горький), Ангустиас («Бернарда Альба йорты», Ф.Г.Лорка), Иветта («Кураж ана һәм аның балалары», Б.Брехт), Хелен («Могҗиза тудыручы», У.Гибсон), Мәдинә («Ай булмаса, йолдыз бар», Т.Миңнуллин), Хәмдия («Ак калфак», М.Фәйзи).

**ӘСХӘДУ́ЛЛИН** Гамил Габдулла улы (19.3.1959, Ширәмәт (хәзер Түбән Кама) р-ны Шәңгәлче а.), эстрада артисты, ТРның халык артисты (2010). Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тын тәмамлый (1986). 1979 елдан «Нефтехимик» клубында үзешчән сәнгать түгәрәгендә шөгыльләнә (Түбән Кама ш.), Шаяннар һәм тапкырлар клубының актив катнашучысы, аннары җитәкчесе, соңыннан шуның нигезендә «Мунча ташы» юмористик театры оеша. 2005 тән театрның җитәкчесе, «Көмеш туй», «Зыянлы файда», «Эт чаба дип, бет чаба», «Заманына күрә һәркем түрә» һ.б. спектакльләрнең авторы, куючысы, рольләр башкаручы.

**ӘҮХӘДИ́ЕВА** Людмила Александровна (18.8.1953, Мамадыш р-ны Соколка а.), педагог, пед. фән. д-ры (2009). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), СССР ПФАнең Һөнәри-техник пед. фәнни-тикшеренү ин-тында, ВЦСПСның Бөтенсоюз хезмәтне саклау фәнни-тикшеренү ин-тында. 1980–85 елларда Казан мәктәпләрендә, 1986–88 дә Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лында, 1991–95 тә РМАнең Урта махсус белем бирү ин-тында эшли. 1995 тән Казан пед. ин-тының (2005 тән — Татар гуманитар-пед. ун-ты) пед. кафедрасында, 2008 дән

пед. һәм этнопед. тарихы каф. профессоры, 2011 дән Казан ун-ты Филол. һәм сәнгать ин-тының гуманитар-сәнгати белем бирү теориясе һәм технологиясе кафедрасында. Хезмәтләре пед. өлкәсендә коммуникатив сәләтләр һәм культура формалаштыруга карый.

**ӘФЛӘТУ́НОВА** Фатыйма Фәрди кызы (1921, хәзер Оренбург өлкәсенең Абдулин р-ны Яңа Якуп а. – 30.8.2004, шунда ук), тракторчы-машинист, Соц. Хезмәт Герое (1966). Тракторчылар курсларын тәмамлый (1941). 1938–58 елларда Абдулин машина-трактор станциясендә эшли, бер үк вакытта тракторчы хатын-кызлар бригадасын җитәкли. 1958–84 тә Абдулин р-ны «Дружба» к-зында. Герой исеме ашлык җитештерүне арттыру һәм хәзерләү, техниканы югары җитештерүчәнлек б-н файдалану эшендә аерым уңышлары өчен бирелә. РСФСР ЮС депутаты (1967–71). Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘДИ́ЕВА** Роза Шәйхәйдәр кызы (13.8.1979, БАССРның Октябрьский ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2012). Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тын тәмамлаганнан соң (2003), шунда ук татар музыкасы кафедрасында эшли, 2004–08 елларда социаль-мәдәни эшчәнлек ф-ты деканы урынбасары, бер үк вакытта, 2007 дән, социаль-мәдәни эшчәнлек кафедрасында 2008 дән Балалар тереклеге иминлеге фәнни үзәге директоры. «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте куркынычсызлыгын арттыру» респ-ка максатчан программасы авторларының берсе (2010–12). Хезмәтләре тормыш иминлеге мәсьәләләренә карый.

**ӘХМӘДУ́ЛЛИН** Роберт Рафаэль улы (2.10.1966, Минзәлә ш.), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013). Казан ун-тын (1990), РФ Хөкүмәте каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (2001) тәмамлый. 1990–95 елларда Татарстан «Татнефтепромхим» терр. идарәсендә участок, цех башлыгы булып эшли. 1995 тән «Татнефть» АҖдә: нефть һәм газ чыгару мастеры, инженер-технолог, «Әлмәтнефть» НГДУының нефть һәм газ чыгару цехы башлыгы, бүлек башлыгы (2003 тән), «Нурлатнефть» НГДУының баш инженеры – башлыкның беренче урынбасары (2008 дән). Уйлап табуга 42 патенты бар. Дәүләт бүләге нефть әзерләү сыйфатын Урал-Идел буендагы чыганаклар шартларында яхшырту технологиясен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘТВӘЛИ́ЕВ** Рамил Нәфис улы (17.10.1962, Бөгелмә ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Ульянов политехник ин-тын (1985), Мәскәү нефть һәм газ ин-тын (1991) тәмамлый. 1986 елдан «Татнефть» АҖдә: электромонтёр, инженер-метролог, инженер-технолог, «Әлмәтнефть» НГДУының цех башлыгы урынбасары (1995 кә кадәр); җитештерү бүлеге башлыгы урынбасары, техник бүлек башлыгы (2000 нән), АҖнең җитештерү бүлеге башлыгы (2002 дән). Уйлап табуга 60 ка якын патенты бар. Дәүләт бүләге нефть чыгару процессларын идарә һәм оператив контрольлек итү буенча корпоратив мәгълүмати система эшләүдә һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ӘХМӘТҖА́НОВ** Рөстәм Рәсим улы (31.5.1959, Лениногорск ш.), автоматлаштырылган идарә системасы буенча инженер, икътисад фән. канд. (2007), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан авиация ин-тын (1985), РФ Хөкүмәте каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (2001) тәмамлый. 1985–99 елларда ТатНИПИнефтьтә эшли. 1999 дан «ТатАСУнефть» идарәсе башлыгы, 2002 дән «Татнефть» АҖ баш инженеры урынбасары. 2011 дән «Татинтек» ҖЧҖ (Әлмәт ш.) ген. директоры. Хезмәтләре нефть чыгаручы пр-тие б-н идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыруга карый. Уйлап табуга 6 патенты бар. Дәүләт бүләге нефть чыгару процесслары б-н идарә һәм оператив контрольлек итү буенча корпоратив мәгълүмати система эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘТҖА́НОВА** Фирая Казбек кызы (6.9.1960, Әгерҗе р-ны Кыдырлы а.), а.х. терлекләрен тукландыру өлкәсе белгече, биол. фән. д-ры (2010). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнан соң (1984), шунда ук а.х. терлекләрен тукландыру кафедрасында эшли. Хезмәтләре техноген пычрану шартларында үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясенә токсикантлар катнашуны (ш.и. авыр металлар) киметү чараларын эшләү өлкәсенә карый.

**ӘХМӘТҖА́НОВЛАР**, цирк артистлары гаиләсе: **Ринат Рифкать улы** (20.3.1950, Казан), цирк артисты, һава гимнасты, ТРның халык артисты (1994). 1971 елдан Казан циркында, 1985 тән «Әйләнмәле аппаратлы гимнастлар» номерының артисты һәм җитәкчесе. Аның «Феерия пасодобль ритмнарында» номеры Россиянең һәм чит илләрнең барлык эре шәһәрләрендә дә күрсәтелә. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1985); **Кадрия Исламетдин кызы** (18.6.1952, Казан), цирк артисты, акробат, ТАССРның атказ. артисты (1990). Казан циркы каршындагы Мәскәү үзәк цирк сәнгате студия-ф-лын тәмамлый (1970). 1993 тән ире җитәкчелегендәге номерлар ассистенты; **Ленара Ринат кызы** (10.6.1977, Казан), цирк артисты, һава гимнасты, ТРның атказ. артисты (2008). Казан мәдәният һәм сәнгать академиясен тәмамлый (2000). 1993 тән этисе номерында эшли, Монте Карлода (2001), Висбаденда (ГФР, 2003), Гренобльдә (Франция, 2007) үткәрелгән халыкара цирк сәнгате фестивальләре лауреаты; **Данияр Ринат улы** (17.11.1984, Казан), цирк артисты, акробат. 2000 нән Россия дәүләт циркы системасында, «Түгәрәк квадрат» номеры җитәкчесе — иркен чыбыкта эквилибр. Монте Карлодагы 14 нче халыкара цирк фестиваленең алтын призы (2002), Висбадендагы Европа яшьләр циркы фестиваленең бронза призы лауреаты (ГФР, 2004).

**ӘХМӘ́ТОВ** Линар Гыймазетдин улы (16.3.1959, Мөслим р-ны Вәрәшбаш а.), педагог, пед. фән. д-ры (2009), проф. (2011). Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), шунда ук хезмәт һәм икътисад укыту методикасы кафедрасында эшли, каф. мөдире (1997 елдан), технол.-икътисад ф-ты деканы (2001 дән), уку-укыту эшләре буенча проректор (2003 тән), 2011 дән Казан ун-тының Алабуга ин-тында директорның тәрбия эшләре һәм социаль үсеш буенча урынбасары. Хезмәтләре укытучының һөнәри эшчәнлегендә интеграцияләнгән мәгълүмати тирәлекне өйрәнүгә карый. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2005).

**ӘХМӘ́ТОВ** Равил Нургали улы (25.5.1948, Южно-Сахалинск ш.), ракета төзү һәм космик аппаратлар өлкәсе белгече, техник фән. д-ры (2012), РФнең атказ. конструкторы (2011). Куйбышев политехник ин-тын (хәзер Самара техник ун-ты) тәмамлаганнан соң (1973), «Прогресс» ракета-космик үзәгендә («РКЦ «Прогресс») инженер, өлкән инженер, төркем башлыгы, бүлек башлыгы урынбасары, бүлек башлыгы, бүлекчә башлыгы урынбасары — «ЦСКБ-Прогресс» бүлеге башлыгы булып эшли. 2006 елдан ген. директорның 1 нче урынбасары–генераль конструктор – Үзәк махсуслаштырылган конструкторлык бюросы («ЦСКБ-Прогресс») башлыгы. Аның җитәкчелегендә «Союз 2. 1б» йөрткеч ракета эшләнә. Хезмәтләре очу аппаратларын проектлау, конструкцияләү һәм җитештерүгә, геомәгълүмати технологияләр, автомат идарә системаларын проектлау һәм куллануга карый. РФ Хөкүмәтенең космик эшчәнлек өлкәсендәге Ю.Гагарин исем. бүләге лауреаты (2016). Почёт, Дуслык орденнары, медаль б-н бүләкләнә. «Союз-2» йөрткеч ракетасын эшләү, сынау һәм гамәлдә куллануга кертkән өлеше өчен РФ Хөкүмәте бүләгенә лаек була (2016).

**ӘХМӘ́ТОВ** Рөстәм Рәфгать улы (27.9.1956, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2011), проф. (2012). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1981). 1981–84 елларда Мәскәү химия машиналары төзү ин-тында укыта. 1989–91 дә СССР ФАнең Казан ф-лында икътисад бүлеге фәнни хезмәткәре, 1991–98 дә «Аверс» банкында кыйммәтле кәгазьләр бүлеге җитәкчесе, 1999–2004 тә ТР ФАнең Социаль-икътисад һәм хокук фәннәре ин-тында икътисад бүлеге фәнни хезмәткәре, 2005–08 дә «ТИСБИ» идарә ун-тында финанс менеджменты каф. доценты, 2008 дән Казан ун-ты Идарә, икътисад һәм финанслар ин-тында корпоратив идарә каф. доценты. Хезмәтләре финанс базарын, икътисад һәм финанс кризислар һәм циклларын, финанс базарының тотрыклылыгын бәяләү алымнарын, финанс активларын бәяләү методикасын өйрәнүгә карый.

**ӘХМӘ́ТОВ** Таһир Мөнәвир улы (11.5.1962, Казан), а.х. терлекләрен үрчетү буенча белгеч, биол. фән. д-ры (2010). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлый (1985). 1987 елдан шунда ук (бүленеп) а.х. терлекләре генетикасы һәм селекциясе (2000 гә кадәр), терлекчелек технологиясе (2007 дән) кафедраларында эшли. 2001–07 дә Казан аграр ун-тында. Хезмәтләре а.х. терлекләре селекциясендә заманча

молекуляр-генетик алымнар файдалануга карый.

**ӘХМӘ́ТОВА** Лилия Тимерхан кызы (15.12.1964, Менделеевск ш.), химик-технолог, химия фән. канд. (1992), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Казан технол. ун-тын (1987), Казан ун-тын (2002) тәмамлый. 1993–2002 елларда «Сәмруг» респ-ка фәнни-гамәли үзәге акц. җәмгыятендә эшли, 2002 дән «АНТ» ҖЧҖ директоры урынбасары. Хезмәтләре инновацион продуктлар составын һәм үзлекләрен, аларның кеше һәм хайван организмындагы биохимик һәм физиол. процессларга тәэсирен тикшерүгә карый. Дәүләт бүләге «Нәорганик матдәләрнең химик технологиясе» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ӘХМӘ́ТШИН** Равил Кәлимулла улы (23.4.1960, Әлмәт р-ны Түбән Абдул а.), хакимият эшлеклесе, хокук белгече, юридик фән. канд. (2006), ТРның атказ. юристы (2010), полиция генерал-майоры (2007). Казан ун-тының филол. (1982), юридик (1992) ф-тларын, РФ Хөкүмәте каршындагы Финанс академиясен (1992) тәмамлый. 1984–94 елларда ТР Эчке эшләр министрлыгы органнарында. 1994 тән ТР Салым полициясе департаментында оператив хезмәт башлыгы урынбасары – оператив хезмәтнең 4 нче бүлеге башлыгы, 1995–2000 дә ТР Салым полициясе департаментының Казан шәһәре буенча бүлек башлыгы, 2000–02 дә РФ Салым полициясе федераль хезмәтенең ТР буенча идарә башлыгы урынбасары. 2002 дән Мәскәүдә: РФ Салым полициясе федераль хезмәтенең Мәскәү шәһәре буенча идарә башлыгы урынбасары, 2003 тән Эчке эшләр баш идарәсенең Мәскәү шәһәре буенча оператив идарә башлыгы, 2006 да Мәскәү шәһәре Эчке эшләр идарәсенең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә тәртип бозучылар б-н көрәш буенча идарә башлыгы, 2006–10 да РФ Эчке эшләр министрлыгының Баш мәгълүмат-аналитика үзәге башлыгының беренче урынбасары. 2010 нан ТРның РФдәге Тулы вәкаләтле вәкиле, 2013 тән ТР Премьер-министры урынбасары – ТРның РФдәге Тулы вәкаләтле вәкиле. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ӘХМӘ́ТШИН** Рәис Асылгәрәй улы (1.1.1957, Азнакай р-ны Түбән Якый а.), инженер-механик, ТРның атказ. нефтьчесе (2006), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Мәскәү нефтехимия һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1984). 1974 елдан «Татнефть» АҖдә: «Сөләйнефть» НГДУында слесарь-ремонтчы, оператор, нефть һәм газ чыгару цехы мастеры, «Җәлилнефть» НГДУының нефть промыселы, үзәк инженерлык-технол. хезмәте башлыгы, баш инженер (2009 дан). Дәүләт бүләге нефтьне промыселдан транспортлауның ышанычлыгын арттыру буенча техник ысуллар комплексын тикшерүдә һәм сәнәгатьтә гамәлгә ашыруда катнашканы өчен бирелә.

**ӘХТӘ́МОВ** Оскар Зөфәр улы (25.11.1972, Казан), инженер-икътисадчы, икътисад фән. канд. (1999), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). Казан техник ун-тын тәмамлаганнан соң (1995), «Казан фотоматериаллар институты» АҖдә эшли, ген. директор (2005 елдан). Хезмәтләре инвестицияләр базары өлкәсенә һәм аның хәзерге заман базар икътисадындагы роленә карый. Дәүләт бүләге углеводород чималын күкертле кушылмалардан чистартучы фталоцианин катализаторларын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

**ӘЮ́ПОВ** Айдар Айрат улы (3.8.1975, Самара өлкәсенең Тольятти ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2008), проф. (2009). Казан финанс-икътисад ин-тын (1997), «ТИСБИ» идарә академиясен (2007) тәмамлый. 1997–2006 елларда «ТИСБИ»дә эшли, кыйммәтле кәгазьләр һәм финанс инжинирингы каф. мөдире (2000 нән), икътисад ф-ты деканы (2005 тән). 2006–11 дә Тольятти ун-тында: икътисад һәм финанс каф. мөдире, читтән торып уку (2009 дан), дистанцион укыту (2010) ин-тлары директоры. 2011 дән Казан ун-тының Өзлексез белем бирү ин-ты директоры. Хезмәтләре финанс базарларында инновацион үзгәрешләр мәсьәләләренә карый.

**ӘЮ́ПОВА** Ирада Хафизҗан кызы (13.7.1971, Баку), хакимият эшлеклесе, ТРның атказ. икътисадчысы (2014). Әзәрбайҗан нефть академиясен (1993), Татарстан эшмәкәрлеккә ярдәм итү ин-тын (2002) тәмамлый. 1994–98 елларда «Түбәнкамашин» ААҖдә программалаучы инженер, 1998–2000 дә Түбән Кама коммерция үзәгендә баш белгеч. 2000–04 тә Казан шәһәре эшмәкәрлеккә ярдәм итү ком-тында бүлек башлыгы, ком-т рәисе урынбасары. 2004–05 тә Казан шәһәре хакимиятендә кадрлар бүлеге башлыгы. 2005–06 да Казан шәһәре эшмәкәрлеккә ярдәм итү ком-ты рәисе. 2006–08 дә ТР Икътисад министрлыгында бүлек башлыгы. 2008–11 дә ТР мәдәният министры урынбасары, 2011–15 тә ТР мәдәният министрының беренче урынбасары. 2015–16 да ТР МК каршындагы Баш архив идарәсе башлыгы, 2016–18 дә ТР Архив эшләре буенча дәүләт ком-ты рәисе. 2018 дән ТР мәдәният министры.

**ӘЮ́ПОВА** Роза Галләметдин кызы (8.2.1959, Чуаш Респ-касының Батыр р-ны Шыгырдан а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2011). Чуаш пед. ин-тын тәмамлый (1982). 1982–83 елларда Чуаш Респ-касының Кыр Бикшиге урта мәктәбендә инглиз һәм немец телләре укыта. 1984–92 дә Казанда «Союзнефтепромхим» фәнни-тикшеренү ин-тында инженер-тәрҗемәче, 1992 дән Казан ун-тында, герман филол. каф. профессоры (2011 дән). Хезмәтләре чагыштырма тел белеме, тәрҗемә, фразеология, фразеография мәсьәләләренә карый. 2006 дан Казан шәһәре Мәгариф идарәсе б-н берлектә Шәраф Мөдәррис исем. яшь тәрҗемәчеләр конкурсын оештыра.

**БА́БИЧ** Михаил Викторович (28.5.1969, Рязань ш.), дәүләт эшлеклесе. М.В.Захаров исем. Рязань югары хәрби командирлар элемтә уч-щесен (1990), Мәскәү икътисад, менеджмент һәм хокук ин-тын (1998), Дәүләт идарә академиясен (Мәскәү, 2000), РФ Кораллы көчләре Ген. штабы академиясен (2005) тәмамлый. 1986–94 елларда хәрби хезмәттә, сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1995–98 дә «Антей» корпорациясе» АҖ җитәкчеләренең берсе. 1999–2000 дә «Азык-төлек базарын җайга салу буенча федераль агентлык» баш идарәсе ген. директорының 1 нче урынбасары. 2000 дә Мәскәү өлкәсе хөкүмәте рәисенең 1 нче урынбасары. 2001 дә Иваново өлкәсе хакимияте башлыгының 1 нче урынбасары. 2002–03 тә Чечен Респ-касы Хөкүмәте рәисе; 2003 тә Россия федераль иминлек хезмәтенең Чикне саклау хезмәте директоры урынбасары; 2003 тән РФ Дәүләт Думасы депутаты, Думаның оборона буенча ком-ты рәисе урынбасары. 2011–18 дә Идел буе федераль округында РФ Президентының вәкаләтле вәкиле. 2018 дән РФнең Белоруссия Респ-касындагы гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе. 2019 дан РФ икътисади үсеш министры урынбасары. Хезмәтләре икътисадка, пр-тие җитәкчесенең персонал буенча карарлар кабул итү хезмәтен камилләштерү мәсьәләләренә карый. 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Александр Невский, Почёт, Дуслык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**БА́БКИНА** Софья Сауловна (11.7.1962, Казан), химик, химия фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1984), СССР ФА Казан ф-лының Органик һәм физик химия ин-тында эшли. 1987 дән Казан ун-тында, нәорганик химия каф. профессоры (2005 тән). Хезмәтләре ферментлар, иммунологик реакцияләр компонентлары, ДНК нигезендә электрохимик биосенсорлар; биосенсорлар һәм тест-системалар ярдәмендә биол. актив матдәләрне анализлау алымнарын эшләүгә; төрле авыруларны диагнозлау һәм аналитик алымнар ярдәмендә фарм. препаратларны билгеләүгә карый. Табигый объектларда, ашамлыкларда һәм кан сывороткасында авыр металлар булуын билгеләүне контрольдә тоту максатында экологик чара буларак ДНК нигезендә биохимик сенсор тәкъдим итә. Экспресс һәм селектив генетик анализ өчен ДНК-зонд конструкциясе эшли. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**БАБЫ́НИН** Александр Александрович (30.3.1972, Украина ССР, Львов ш.), инженер-технолог, ТРның атказ. химигы (2006), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). 1994 елда Азов буе техник ун-тын (Украина, Мариуполь ш.) тәмамлаганнан соң, «Донбассэкология» фәнни-җитештерү пр-тиесендә эшли. 1995–2003 тә «Оргнефтехимзаводы» инженерлык-җитештерү тресты АҖдә (Мәскәү) инженер-технолог. 2003–05 тә «Түбән Кама нефть эшкәртү заводы» АҖнең баш инженеры урынбасары. 2004–05 тә «Татарстан–Корея нефть-химия компаниясе» АҖнең (Түбән Кама ш.) ген. директоры урынбасары. 2005–11 дә «ТАИФ-НК» АҖдә, ген. директор (2006 дан). «ИНКО-ТЭК» АҖ ген. директоры (2011 дән). Уйлап табуга 2 патенты бар. Дәүләт бүләге җиңел углеводород чималын күкертле кушылмалардан бер стадиядә чистарту процессын эшләүдә һәм

гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2009).

**БАЖА́ЙКИН** Станислав Георгиевич (9.1.1944, Амур өлкәсенең Завитая р-ны Завитая пос.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2000). 1969 елда Урал ун-тын (Свердловск ш.) тәмамлаганнан соң, Энергия ресурсларын транспортлау проблемалары ин-тында (Уфа ш.) эшли, насос-энергетик җиһазларны файдалану бүлеге мөдире (1993 тән), директор урынбасары (2002 дән). Хезмәтләре үзәктән кугыч һәм винтлы насосларны проектлау, файдалану, сыеклыклы газ катнашмаларын һәм үзле сыекчаларны кудыру мәсьәләләрен тикшерүгә карый. Үзәктән кугыч насосларның этем сыйфатламалары кудырылган мохиттә сыгылмалы дулкыннар (тавыш) таралу тизлегенә һәм үзле сыекчаларның кырый катламы калынлыгына бәйлелеген ачыклый. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФАнең И.М.Губкин исем. бүләге (2002), ТР Дәүләт бүләге (2012) лауреаты.

**БА́ЖИНА** Ираида Александровна (11.7.1940, Свердловск өлкәсенең Махнёвск р-ны Турутина а.), педагог, пед. фән. д-ры (2003). Түбән Тагил пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Свердловск өлкәсенең Алапаевск шәһәрендә урта мәктәптә укыта, 1964 елдан Казан мәктәпләрендә. 1975 тән Укытучылар белемен камилләштерү ин-тында, 1976 дан Казан пед. ин-тының (2005 тән Татар гуманитар-пед. ун-ты) химия кафедрасында, 2011 дән Казан ун-тының Пед. һәм психол. ин-тында белем бирүдә менеджмент кафедрасында. Хезмәтләре химия укыту методикасына, белем бирүне төбәкләштерү мәсьәләләренә карый.

**БАЗАРЕ́ВСКАЯ** Венера Гыйльметдин кызы (7.11.1961, Ютазы р-ны Алма-Ата а.), геолог, геол.-минерал. фән. канд. (2004), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Казан ун-тын тәмамлый (1988), ТатНИПИнефтьтә эшли, эзләү һәм разведкалау геологиясе бүлеге башлыгы (2001 елдан). Хезмәтләре геологиягә, нефть ятмаларын эзләүгә һәм әзерләүгә карый. Дәүләт бүләге «Татнефть» АҖ ресурслар базасын үстерү өчен комплекслы алымнарның фәнни нигезе һәм аларны сәнәгатькә кертү» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**БА́ИШЕВ** Батыр Усман улы (15.8.1949, Үзбәк ССРның Бохара өлкәсе Кызылтәпә ш.), кинорежиссёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2009). Бөтенсоюз кинематография ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1980). 1980–95 елларда Ташкент документаль һәм фәнни-популяр фильмнар студиясендә режиссёр, 1997 дән Казан кинохроника студиясендә. Медицина, экология проблемаларына караган «Тасма» — кичә, бүген...», («Тасма» — вчера, сегодня...»), «Календарьдагы кызыл көн, яки Без яңадан СССРда» («Красный день календаря, или Мы снова в СССР»), «Шырдан авылы сәйяре сабаклары» («Уроки странника из деревни Ширданы») документаль фильмнарын төшерә.

**БАКА́ЕВ** Альберт Флюр улы (9.1.1964, Чиләбе ш. – 5.6.2009, шунда ук), паралимпияче спортчы (йөзүче), Россиянең атказ. спорт остасы (1996). Урал физик культура академиясен тәмамлый (2003). Дөнья (1994), Европа (1997) чемпионы. IX, X, XI, XII, XIII Паралимпия уеннарының җиңүчесе һәм призёры: Барселона (1992, Испания — бронза), Атланта (1996, АКШ — алтын, көмеш), Сидней (2000, Австралия — 2 көмеш, 2 бронза), Афина (2004, Греция — көмеш), Пекин (2008, Кытай). Бөтендөнья Инвалидлар уеннары (2003, Яңа Зеландия) җиңүчесе һәм Европа Кубогы (2003, Чехия) иясе. Россия Паралимпия ком-ты вице-президенты (2002 дән). Чиләбе шәһәренең мактаулы гражданы (2002). Дуслык ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**БАКИ́РОВ** Илшат Мөхәммәт улы (2.1.1952, БАССРның Туймазы р-ны Ярмөхәмәт а.), нефтьче, техник фән. д-ры (2013). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1974), ТатНИПИнефтьтә эшли, директор урынбасары (2008 елдан). Хезмәтләре нефть чыганакларын эшкәртүгә карый. Карбонат катламнардан нефть чыгару системаларын камилләштерә. Чыганакны эшкәртүнең соңгы стадиясендә сыеклыкны алуны җайлау һәм пластларга гидродинамик тәэсир итүне камилләштерү алымнарын эшли. Уйлап табуга 17 патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012).

**БАКИ́РОВ** Нәҗип Баһман улы (16.4.1944, Аксубай р-ны Иске Кыязлы а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2009), РФнең мактаулы җир төзүчесе (2001), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2004). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), Аксубай р-нында эшли: Вахитов исем. к-зның баш агрономы (1969–70), «Октябрь» к-зы рәисе (1970–73), район советы башкарма ком-тының а.х. идарәсе башлыгы (1973–77). 1977–82 елларда район советы башкарма ком-ты рәисе, 1982–90 да КПССның Әлки райкомы 1 нче секретаре. 1990–95 тә ТР ЮС секретариаты башлыгы, 1995–98 дә ТР МК Аппараты җитәкчесе, 1998 дән «Республика «Җир» кадастр үзәге» АҖ ген. директоры (Казан). Хезмәтләре зона сөрүле туфракларының агрохимик сыйфатлары турында мәгълүмат банкы булдыруга, сабан ашлыгының нормалаштыру факторын ачыклап, агрохимик сыйфатлары һәм уңышлылыгының бәйлелеген өйрәнүгә; туфрак уңдырышлылыгын идарә итү концепциясен булдыруга карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**БАКИ́РОВ** Рафаил Мулланур улы (7.07.1946, Чиләбе өлкәсенең Магнитогорск ш.), баянчы, композитор, публицист, ТРның һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1997, 2012). Казан консерваториясен тәмамлый (1970). 1966 елдан музыка мәктәбендә, 1971 дән музыка уч-щесендә укыта, 1998 дән Магнитогорск консерваториясендә халык оркестр музыка уен кораллары каф. профессоры. «Яшьлек» халык татар-башкорт җыр һәм бию ансамбле (1971–96), консерватория каршындагы «Айгөл» муз. ансамбле (1989), шәһәр татар мәдәни үзәге (1994–97) җитәкчесе.

**БАКИ́РОВА** Индира Наил кызы (10.1.1956, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (2004), проф. (2005). Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук эшли. Хезмәтләре полиуретан материаллар — монолит, газ тутырылган, җилемле, лак-буяу материаллары һәм герметик композицияләрнең синтезына, үзлекләренә һәм кулланылуына карый. Б. тикшеренүләренең нәтиҗәләре полиуретан җитештерүдә кулланылучы ресурс саклаучан һәм экологик яктан алдынгы технологияләр эшләүдә һәм аларның калдыкларын химик деструкция юлы б-н полиолларга әйләндерүдә файдаланыла (химик, нефть, машиналар төзү, оборона һ.б. сәнәгать тармакларында гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**БАКЫ́ЕВА** Һава Хәмидулла кызы (3.8.1932, хәзер Түбән Новгород өлкәсенең Пилнә р-ны Петрякс а. – 30.7.2003, Тверь ш.), тукучы, Соц. Хезмәт Герое (1974). 1949–98 елларда А.П.Вагжанов исем. Калинин (хәзер Тверь) эрләү-туку ф-касында эшли. Тармакта күп станокларда эшләүчеләр хәрәкәтенә башлангыч бирүчеләрнең берсе. Герой исеме 8 нче бишьеллык (1966–70) планнарын уңышлы үтәгәне өчен бирелә. КПССның 19 нчы Бөтенсоюз конференциясе делегаты (1988). 1974–84 тә СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**БАЛЬЦ** Владимир Александрович (19.1.1871, С.-Петербург — 1931, Көнчыгыш Себер краеның Тулун округы Братское а. янында), хокук белгече, сенатор (1917), яшерен советник (1917). Дворяннар нәселеннән. Хокук белеме уч-щесен тәмамлый (С.-Петербург, 1891). 1891–94 елларда Петербург мәхкәмә палатасында хезмәт итә. 1894–96 да Ревель округ мәхкәмәсендә суд тикшерүчесе. 1896–99 да Митава, 1899–1901 дә Витебск, 1901–03 тә Петербург, 1903–06 да Түбән Новгород округ мәхкәмәләре прокуроры иптәше (урынбасары). 1906–09 да Петербург мәхкәмә палатасы прокуроры иптәше, 1909–15 тә Казан мәхкәмә палатасы прокуроры. 1915–16 да Россия Юстиция министрлыгының 2 нче департаменты директоры. 1916–17 дә эчке эшләр министры иптәше. 1917 дә Сенатның 1 нче һәм кассация департаментларында, хәрби ведомстволар буенча эш урыныннан явызларча файдалануларны тикшерү комиссиясе рәисе. Окт. рев-циясеннән соң Кострома губернасында, Ленинградта яшерен сәяси эштә. 1931 дә кулга алына һәм Себергә сөрелә, шул ук елда вафат була. «Беренче эшче депутатлар Советы өстеннән хөкем: Прокурор хатирәләре» («Суд над первым Советом рабочих депутатов: Воспоминания прокурора». М., 1929) мемуарлары, балалар өчен повестьлар һәм хикәяләр авторы.

**БАРИ́ЕВ** Радик Зөфәр улы (30.6.1970, Казан), драма актёры, режиссёр. ТРның халык артисты (2017). ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2019). Казан мәдәният һәм сәнгать академиясен тәмамлаганнан соң (1995), Татар акад. театрында эшли. Сәхнә пластикасына ия актёр. Б.ның проф. баш-

кару осталыгы төрле жанрдагы тормышчан, кабатланмас, үзенчәлекле образлар иҗат итү мөмкинлеге тудыра: Петр («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир), Яков, Дорн («Акчарлак», А.Чехов), Альфред, Фирдәвес, Фәридун («Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре», «Баскетболист», М.Гыйләҗев), Вандалино («Биюче», Лопе де Вега), Шурик («Җанкисәккәем», Т.Миңнуллин), Поль Тагарель («Тол ханымда тукталыш», Э.Лабиш), Герман («Юлбасарлар», Ф.Шиллер), Роберто («Гаугалы гаилә» Э.де Филиппо), Хан («Җирән чичән һәм Карачәч сылу», Н.Исәнбәт), Котэ («Ханума», А.Цагарели), Көтүче («Кара чикмән», Г.Хугаев), Тимуш («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Рассуханов («Телсез Күке», З.Хәким), Вафа («Курчак туе», М.Гыйләҗев, Р.Хәмид; Г.Исхакый әсәрләре буенча), Сиражетдин («Банкрот», Г.Камал; «Иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге, 2014), Дон Жуан («Дон Жуан», Ж.-Б.Мольер; «Иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге, 2016), Нәкыйп («Килмешәк», С.Гаффарова), Баһман Кочубеевич («Бию пәрие», И.Зәйниев) һ.б. Режиссёр буларак «Сөясеңме, сөймисеңме...» (Ф.Бүләков), «Кечтүкле уен» (И.Зәйниев), «Ут күршеләр» (С.Юзеев) спектакльләрен сәхнәгә куя. Д.Сиражиев исем. театраль бүләк лауреаты (2010). ТР Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (2000).

**БАРИ́ЕВ** Тәлгать Рәүф улы (15.8.1950, Казан), журналист, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), шунда ук социол. лаб-ясендә эшли. 1987–90 елларда «Вечерняя Казань», 1990–94 тә «Молодёжь Татарстана» г-талары хәбәрче-күзәтүчесе. 1994 тән ТР ФА президентының, 2004 тән Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма ком-ты рәисенең киңәшчесе. 1995 тән Татар ПЕН-үзәге әгъзасы. 2005–12 дә Бөтентатар иҗтимагый үзәге рәисе. Хезмәтләре татар мәдәнияте, сәясәт һәм милли мәсьәләләргә карый.

**БАСО́С** Георгий Юрьевич (7.2.1959, Бөгелмә ш.), нефтьче, техник фән. канд. (2003), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1981). 1996 елдан ТатНИПИнефтьтә эшли, нефть скважиналарын эшләтү һәм ремонтлау бүлеге секторы мөдире (1999 дан). Хезмәтләре нефть чыганакларын эшкәртүгә карый. Дәүләт бүләге авыр чыгарылулы нефть запасларын чыгару нәтиҗәлелеген арттыру максатында яңа технологияләрне һәм җиһазларны эшләүдә һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**БАҺАВЕТДИ́НОВ** Флёр Нуретдин улы (10.1.1958, Мөслим р-ны Иске Вәрәш а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2005), ТР ФА мөхбир әгъзасы (2007), ТРның атказ. юристы (1997). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1980). 1980–82 елларда Минзәлә р-ны прокуратурасы тикшерүчесе. 1982–87 дә ТАССР Прокуратурасының өлкән тикшерүчесе, 1987–90 да аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе. 1990–96 да Әлмәт шәһәре прокуроры. 1996–97 дә ТР прокуроры урынбасары. 1997–2002 дә Казан шәһәре прокуроры. 2002–03 тә ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департамент җитәкчесе урынбасары, 2003–04 тә җитәкчесе. 2004 тән ТР Конституция мәхкәмәсе судьясы. Бер үк вакытта, 2007–11 дә, Социаль белем бирү академиясенең (Казан) җинаять хокукы һәм процессы каф. мөдире, 2011 дән җинаять процессы каф. профессоры. Хезмәтләре юридик фәннәр тарихына, җинаять хокукы һәм процессына, криминалистикага, прокурор күзәтчелеге җинаятьләрне тикшергәндә гражданнарның гомуми һәм шәхси мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләренә карый. А.Т.Бажанов, Г.Б.Баһаветдинов, Г.М.Солнцев, Ф.Н.Фәткуллин һ.б. турында китаплар авторы. ТР Язучылар берлеге әгъзасы (1996).

**БАҺАВЕТДИ́НОВА** Дания Борһан кызы (7.1.1932, Кама Тамагы р-ны Җәмәки а. — 28.8.2005, Казан), музей хезмәткәре, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981, 1986). Казан ун-тын тәмамлый (1956). 1957–63 елларда А.М.Горькийның Әдәби-мемориаль музеенда (Казан): аның тарафыннан Г.Коләхмәтов, Һ.Такташ, Ш.Камал, К.Тинчурин, Т.Гыйззәт, С.Сүнчәләй һ.б. язучыларның архивлары табыла һәм музейга алдырыла. 1967 дән ТАССР Дәүләт музеенда (хәзер ТР Милли музее), 1971–88 дә татар әдәбияты бүлеге мөдире. Казанда Ш.Камал, М.Җәлил, Г.Тукай әдәби музейлары, Арча р-ны Яңа Кырлай авылында Г.Тукайның музей комплексы экспозицияләре авторы. «Фотоальбом. Кырлайда Тукай музее» («Фотоальбом. Музей Тукая в Кырлае», 1984), «Шәриф Камалның музей-фатиры» («Музей-квартира Шарифа Камала», 1987), «Казанда Габдулла Тукай музее» («Музей Габдуллы Тукая в Казани», 1989) буклетларының автор-төзүчесе.

**БАҺМА́НОВ** Миңнерәис Алиулла улы (16.9.1951, Чуаш АССРның Батыр р-ны Шыгырдан а. — 18.9.2017, Казан), вет. хирургы, вет. фән. д-ры (1999), проф. (2006). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1977). 1979–89 елларда, бүленеп, Таҗик вет. фәнни-тикшеренү ин-тының вирусология лаб-ясендә (Дүшәмбе ш.). 1989 дан Ульянов а.х. академиясендә: вет. акушерлыгы һәм хирургиясе каф. өлкән укытучысы, доценты, профессоры, мөдире, бер үк вакытта, 2001 дән проректор. 2006 дан Казан вет. медицинасы академиясендә: 2006–11 дә вет. медицинасы ф-ты деканы, бер үк вакытта, 2008–16 да акушерлык һәм вак хайваннар патологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре сыерларда бозаулаганнан соңгы катлаулану очракларын өйрәнүгә, маститларны, эндометритларны һәм соңгылык тоткарлануны, ана дуңгызларда метрит-мастит-агалактий синдромын дәвалау ысулларына, дару препаратлары эшләүгә карый. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2010).

**БАШКИ́РОВ** Владимир Николаевич (29.8.1959, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2007), проф. (2010), ТРның атказ. уйлап табучысы (2003). Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1982), шунда ук эшли, ўзагачның химик технологиясе каф. мөдире (2008 елдан). Хезмәтләре җылыны кондуктив ысул б-н бирү шартларында материалларны басым төшерү ярдәмендә киптерү процессларын тикшерүгә, зарарлы матдәләр бүленеп чыгуга китергән процессларны аппаратура җәһәтеннән тәэмин итүгә, ресурслар һәм энергия саклаучан технология эшләүгә, үзагачны комплекслы химик эшкәртүгә карый. Уйлап табуга 31 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**БАШКИ́РЦЕВА** Наталья Юрьевна (17.7.1968, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2009), проф. (2013). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1992), шунда ук (1992 дән Казан технол. ун-ты, хәзер Казан милли-тикшеренү технол. ун-ты) эшли, 2005 тән нефть һәм нефть химиясе ф-ты деканы, бер үк вакытта, 2010 нан нефть һәм газны химик технол. ярдәмендә эшкәртү каф. мөдире; ш.у. «Панхимтех» фәнни-җитештерү үзәге директоры, Нефть, химия һәм нанотехнология ин-ты директоры вазифаларын башкаручы. Хезмәтләре нефть чыгару барышында катламга комплекслы тәэсир итү технологияләрен эшләү, ш.у. автомобильләр төзү өчен яңа югары технологияле сыеклык составлары җитештерүгә карый. Дәүләт бүләге ТР нефть химиясе комплексының җитештерү потенциалын модернизацияләү барышында пр-тиеләрнең яшәүчәнлеген арттыру һәм сәнәгый куркынычларны киметү механизмын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 25 патенты бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2008). Медаль б-н бүләкләнә.

**БАЯЛИ́ЕВА** Айнагөл Юлдаш (Жолдош) кызы (16.4.1969, Кыргызстан Респ-касы, Ыссык-Күл р-ны Каджи-Сай пос.), анестезиолог-реаниматолог, мед. фән. д-ры (2006), проф. (2018). Кыргыз мед. ин-тын тәмамлый (1992, Бишкәк ш.). 1994–96 елларда Кыргызстан респ-ка клиник хастаханәсендә анестезиолог-реаниматолог булып эшли. 1996–2002 дә Кыргызстан мед. академиясенең анестезиология-реаниматология кафедрасында. 2002–06 да РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының Россия кардиология фәнни-җитештерү комплексы каршындагы Клиник кардиология ин-тының йөрәк-кан тамырлары хирургиясе бүлегендә (Мәскәү). 2006–12 дә Төбәкара клиник диагностика үзәгендә, анестезиология һәм реаниматология бүлеге мөдире (Казан). 2012 дән Казан мед. ун-тының анестезиология һәм реаниматология, һәлакәтләр медицинасы каф. мөдире, бер үк вакытта, 2018 дән, Казан мед. академиясенең анесте-

зиология-реаниматология һәм трансфузиология каф. мөдире. Фәнни эзләнүләре анестезиология-реаниматология, интенсив терапиягә карый. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш анестезиология һәм реаниматология белгече, РФ Анестезиологлар һәм реаниматологлар федерациясенең идарә президиумы әгъзасы, РФ Акушерлык анестезиологлары ассоциациясенең идарә әгъзасы.

**БӘДРЕТДИ́НОВА** Елена Радит кызы (25.5.1972, Кемерово өлкәсенең Новокузнецк ш.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2016). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1994), Казан технол. ун-тында эшли, 2017 елдан информатика һәм гамәли матем. каф. профессоры. Хезмәтләре нефть һәм газ чыганакларын скважиналарны тикшерүнең термодинамик ысулларын кулланып эшкәртү процессларын матем. модельләштерү өлкәсенә карый.

**БӘДРЕТДИ́НОВА** Фирая Равил кызы (18.04.1959, Балтач р-ны Көекбаш а.), журналист, тәрҗемәче. ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (2001). Казан ун-тын (1982), ВЛКСМ ҮК каршындагы Югары комсомол мәктәбен (1987, Мәскәү) тәмамлый. 1980–90 елларда «Яшь ленинчы» г-тасында: хәбәрче, бүлек мөдире, җаваплы секретарь, баш мөхәррир урынбасары; 1990–2000 дә «Салават күпере» ж-лында җаваплы секретарь–баш мөхәррир урынбасары, 2000–09 да «Сөембикә» ж-лының баш мөхәррире (2003 тән директор–баш мөхәррире), 2009–11 дә «Идел» ж-лы баш мөхәррире урынбасары. 2011 дән ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-тының өлкән фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре Казан арты авыллары, Россиядәге татар диаспорасы, татар журналистикасы тарихын өйрәнүгә карый. Төп эше — фәнни текстларны редакцияләү, тәрҗемә итү. Гомуми белем бирүче уку-укыту оешмалары өчен рус теленнән дәреслекләр тәрҗемә итә һәм редакцияли, әдәби-документаль, документаль-публицистик басмаларның әдәби мөхәррире. «Сөембикә ханбикә» җыентыгының (К., 2001; 2006) проект авторы. Журналистлар берлеге әгъзасы (1986). Медальләр б-н бүләкләнә.

**БӘХТИЯРИ́** Мөхәммәтзыя (Мөхәммәтзыя Бәхтияр улы Бәхтияров) (28.2.1877, Казан губ., Казан өязе Мәмдәл а. — 18.1.1974, хәзер Киров өлкәсенең Яңа Смәил а.), дин эшлеклесе, педагог. әл-Мәмдәли Бәхтияр улы. К.Насыйри шәкерте (махсус дәресләр ала). 1899 елда Түнтәр мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, хәзерге Киров өлкәсенең Яңа Смәил авылында 70 елдан артык имам-хатип вазифаларын башкара һәм халык медицинасы нигезендә дәвалау б-н шөгыльләнә. Мәдрәсә шәкертләре өчен арифметика, астрономия дәреслекләре, календарь һәм кульязма китаплар, гарәп хәрефләре б-н укырга-язарга өйрәтү өчен әлифба авторы.

**БӘШИ́РОВ** Фәрид Исрафил улы (31.7.1940, Алабуга ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (2006), проф. (2008). Казан ун-тын тәмамлаганнан (1963) соң, шунда ук эшли, проф. (2006 елдан, бүленеп: 1995–98 дә Оран (Алжир Халык Демократик Респ-касы), 1998–2010 да Конакри (Гвинея Респ-касы) ун-тларында). Хезмәтләре магнитик күренешләр, молекуляр спектроскопиягә карый. Аммоний хлоридында протон магнит релаксациясе тизлекләренең анизотропиясен ача. Кристалларда тормозланган молекуляр хәрәкәт теориясен, аның чәчелү һәм йотылу молекуляр спектрлары тасвирламасына караган кушымталарын алга таба үстерә.

**БЕЛИ́НСКИЙ** Александр Васильевич (6.6.1937, Чуаш АССРның Красные Четаи р-ны Ямаш а.), а.х. җитештерүен механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2005). 1963 елда Казан а.х. ин-тын (хәзер Казан аграр ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 2006 дан агробизнеста машиналар һәм җиһазлар каф. профессоры (бүленеп: 2000–03 тә Татар агробизнес кадрларын яңадан әзерләү ин-тында). Хезмәтләре а.х.нда ашлама куллануның технол. процессларын интенсивлаштыруга карый. Басуларда минераль ашламаларны нәтиҗәлерәк тарату максаты б-н а.х. техникасының конструктив һәм технол. күрсәткечләрен тикшерә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**БЕЛОЗЁРОВ** Альберт Фёдорович (10.9.1937, Вологда өлкәсенең Нюксеница р-ны Воровский исем. с-з пос.), оптика-электрон приборлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2003), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1997), РФнең атказ. машина төзүчесе (2003). Мәскәү югары техник уч-щесен тәмамлый (1960), ГИПОда эшли: директор урынбасары (1975–2005), ген. директор киңәшчесе (2005–09), гыйльми секретарь – ген. директор киңәшчесе (2008 елдан). Бер үк вакытта, 1989 дан, Казан техник ун-тында, оптик-электрон системалар каф. профессоры (2003 тән). Хезмәтләре оптик, оптик-электрон приборлар һәм төрле максатлы комплекслар булдыруга, фаза объектларының голографик интерферометриясен тикшерүгә карый. Б. катнашында газодинамик системаларда агымнарны визуальләштерү өчен приборлар, тепловизорлы төзәү техникасы эшләнмәләре, ш.у. разведка, күзәтү һәм корал б-н идарә итү тепловизорлы системалары эшләнә (РФнең граждannар һәм оборона сәнәгатендә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 33 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2004). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**БЕЛЯ́ЕВ** Адил Бакый улы (5.10.1932, Рязань өлкәсенең Касыйм ш.), төзүче инженер, РСФСРның атказ. төзүчесе (1980). Урта Азия политехник ин-тын (Ташкент) тәмамлый. Мәскәү фәнни-тикшеренү ин-тларында эшли. Хезмәтләре сәнәгый һәм торак объектларын проектлауга һәм төзүгә карый. Борынгыдан билгеле иң мәшһүр татар нәселләренең тарихи шәҗәрәләре һәм аларның хәзерге вәкилләре турында китаплар авторы (360 нәсел, 1000 фамилия).

**БЕЛЯ́ЕВ** Владимир Александрович (8.9.1952, Ставрополь краеның Изобильное а.), политолог, социолог, сәясәт фән. д-ры (2007), проф. (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1975). 1978 елдан Казан химия-технол. ин-тында, 1988 дән Казан техник ун-тында, социол., политология һәм менджмент каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1991–93 тә, ТР Президенты каршындагы Дәүләт советы әгъзасы. Хезмәтләре политология һәм социологиягә, ш.и. Россия интеллигенциясе мәсьәләләренә карый. Уку-укыту-методик ярдәмлекләр авторы.

**БЕРДЫ́ЕВ** Корбан Бики улы (25.08.1952, Төрекмәнстан ССРның Ашхабад ш.), спортчы, тренер (футбол), СССРның спорт остасы (1980). Ашхабад тимер юл транспорты техникумын (1971), Төрекмән ун-тын (1975), Мәскәүдә югары тренерлар мәктәбен (1991) тәмамлый. Спорт б-н 1959 елда Ашхабадта шөгыльләнә башлый. «Строитель» футбол мәктәбендә тәрбияләнә. Ростов өлкәсенең «СКА» (1979–80), Казакъстанның «Кайрат» (1981–85, 1993) командаларында уйный. 1986 дан тренерлык эшендә. «Химик» (Казакъстан, 1986–89), «Кайрат» (Казакъстан, 1991–93, 1994–95), «Гэнчлэрбирлиги» (Төркия, 1993–94), «Ниса» (Төрекмәнстан, 1998–99), Төрекмәнстан җыелма командасы (1999), «Кристалл» (Россия, 2000–01), «Рубин» (Татарстан Респ-касы, 2001–13, 2017–19), «Ростов» (Россия, 2014–16, 2016–17) командаларында тренер һәм баш тренер. Б. җитәкчелегендә «Рубин» футбол командасы Россия чемпионы була (2008, 2009). Россиянең Беренче дивизионында җиңүче (2002), Дуслык Кубогы (2010), Россиянең Суперкубогы (2010, 2012), Россия Кубогы (2011–12), Россия чемпионатында бронза медаль (2003, 2010) иясе. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» (2008), «Дуслык» (2012) орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**БЕРЕГОВО́Й** Антон Николаевич (8.8.1971, Баулы ш.), тау инженеры, техник фән. канд. (2011), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2017). Мәскәү нефть һәм газ ин-тын тәмамлаганнан соң (1994), ТатНИПИнефтьтә: инженер, әйдәп баручы инженер, өлкән фәнни хезмәткәр, лаб. мөдире, 2016 елдан катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру бүлеге башлыгы. Хезмәтләре полимер һәм эмульсияле эремәләр б-н катламнарны суландырганда нефть чыгаруны арттыруга карый. Дәүләт бүләге ТРның нефть чыгару темпларын һәм нефть алу күләмен арттыру өчен технологияләр комплексын эшләүдә һәм аларны сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 40 патенты бар.

**БИКЕ́ЕВ** Игорь Измаилович (7.9.1974, Рязань өлкәсенең Касыйм ш.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2009), проф. (2013). ТРның атказ. юристы (2014). Казан ун-тын тәмамлый (1997). 1998–2002 елларда Мәскәү коммерция ун-тының Казан коммерция ин-тында өлкән укытучы, доцент, 2002 дән

Казан инновацион ун-тында доцент, проф., фәнни эшләр буенча проректор, 1 нче проректор. Җинаять хокукы өлкәсендә аеруча куркыныч объектлар турындагы тәгълимат барлыкка китергән галим буларак танылa, күптомлы Җинаять хокукы энциклопедиясе авторларының берсе; ТРның махсус дәүләт стипендияләре комиссиясе (1999 дан), ТР Президенты каршындагы Коррупциягә каршы көрәш советы (2011 дән), Респ-ка коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча экспертлар төркеме (2012 дән), ТРда коррупциягә каршы көрәш буенча эшчәнлекне координацияләү советы әгъзасы (2015 тән), федераль «Актуальные проблемы экономики и права» ж-лы мөхәррире, федераль «Следователь» ж-лы фәнни-методик советы, «Правосудие в Татарстане» ж-лы редколлегиясе әгъзасы. Коррупциягә каршы көрәшкә багышланган фәнни һәм гамәли эшләр буенча уздырылган 2–4 нче Бөтенроссия конкурсларында җиңүче. Хезмәтләре экстремизмга һәм коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләренә карый.

**БИКМА́ЕВ** Гыйльфан Фәрит улы (22.4.1961, Үзбәкстан ССРның Әндиҗан ш.), астроном, физика-матем. фән. д-ры (2008). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1983), СССР ФАнең Махсус астрофизик обсерваториясендә (Карачай-Чиркәс автономияле өлкәсенең Түбән Архыз а.) эшли. 1995 елдан Казан ун-тында, астрономия каф. профессоры (2009 дан). Бер үк вакытта ТР ФАнең астрофизика лаб-ясе әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре югары нәтиҗәле йолдызлар спектроскопиясенә, актив төшле галактикалар, рентген нурланышы чыганакларына карый. 1995–2005 тә ТЮБИТАК милли оберваториясендә (Төркия, Анталия ш.) Россия-Төркия уртак РТТ-150 телескобын булдыруда һәм гамәлгә кертүдә катнаша. РТТ-150 телескобында Халыкара «Интеграл» галәм орбиталь рентген һәм гамма-обсерваториясе хезмәткәрләре б-н бергә уртак тикшеренүләр алып бара. Якын Галәмдә (Z < 0,1) актив төшле 10 яңа галактика булуын ачыклый. Гравитацион линзаларны, гамма-атылышларның оптик соңарып яктыруларын, Кояш системасының читләрендә Плутон хәрәкәтен тикшерә. Халыкара астрономия берлеге әгъзасы (1997). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009).

**БИКМӨХӘММӘ́ТОВ** Роберт Кәбир улы (30.6.1962, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (2004), проф. (2005). Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлаганнан соң (1983), шунда ук, гимнастика кафедрасында эшли. 1986–89 елларда, институт Чаллы шәһәренә күчерелү һәм аның структурасы үзгәрү белән бәйле рәвештә, спортның циклик булмаган төрләре теориясе һәм методикасы кафедрасында. 1995 тән Казан пед. ин-тының (2005 тән Татар гуманитар-пед. ин-ты) гимнастика һәм чаңгы спорты кафедрасында. 2008 дән Казан ун-тының спорт дисциплиналары каф. мөдире. 2012 дән Идел буе физик культура, спорт һәм туризм академиясенең спорт дисциплиналары теориясе һәм методикасы каф. мөдире. 2015 тән спорт ф-ты деканы. Фәнни тикшеренүләре физик культура һәм спорт өлкәсендә проф. кадрлар әзерләү мәсьәләләренә карый. Уку-укыту ярдәмлекләре авторы.

**БИКТА́ШЕВ** Рафаэль Усман улы (17.10.1947, Арча р-ны Сеҗе а.), а.х. терлекләрен тукландыру өлкәсе галиме, а.х. фән. д-ры (2002). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), шунда ук а.х. терлекләрен тукландыру кафедрасында эшли. 2000 елдан Татар а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының Терлекчелек фәнни-технол. үзәге тикшеренүләр секторы мөдире, 2004 тән «Татнефть» АҖнең «Союз-Агро» ҖЧҖ директоры урынбасары, 2006 дан «Татспиртпром» АҖ ген. директорының үсеш буенча урынбасары, 2008 дән Хайваннарның токсикологик, радиацион һәм биол. куркынычсызлыгы федераль үзәгенең токсикология бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре (Казан). Хезмәтләре терлекчелектә һәм терлек азыгы әзерләүдә ферментлы препаратлар һәм терлекләр рационында югары дисперслы энтеросорбентлар файдалануның нәтиҗәлелеген өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 5 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**БИКЧӘНТӘ́ЕВ** Айрат Мидхәт улы (28.4.1960, Буа р-ны Кырык Садак а.), математик, физика-матем. фән. д-ры (2013). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), шунда ук матем. анализ кафедрасында эшли, бер үк вакытта, 2001 елдан, Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре Гильберт фәзасында линияле операторлар, $C^*$-алгебралар, нәкоммутатив интеграцияләү, квант мантыйкларына карый. Киң класс $C^*$-алгебралар элементларын проектор тапкырчыгышларының азаккы суммалары рәвешендә ачыклауга ирешә. Классик интеграль тигезсезлекләр һәм стат. физика тигезсезлекләренең оператор аналоглары $C^*$-алгебрасындагы уңай функционаллар классы эзләрен чагылдыруын дәлилли. Ярым азаккы фон Нейман алгебраларында идеаль фәзаларның алгебраик, топологик, тәртип үзлекләрен һәм үлчәм буенча туры килү топологиясен билгели.

**БИЛА́ЛОВ** Азат Вәгыйзь улы (12.5.1966, Казан), физика химигы, химик фән. д-ры (2007). Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1989), шунда ук эшли. Хезмәтләре полиэлектролитлар һәм өслекчә-актив матдәләр (ПАВ) эремәләренең физик химиясенә карый. Полимер электролитлар һәм ПАВлар нигезендә супрамолекуляр ансамбльләр барлыкка китерү принципларын эшли, алар исә бирелгән үзлекле һәм функцияле наноматериалларны гамәлдә булдыру өчен файдаланыла ала.

**БИЛА́ЛОВ** Зөфәр (Минзөфәр) Вәгыйзь улы (5.1.1966, Балык Бистәсе р-ны Олы Елга а.), җырчы, ТРның халык артисты (2009). Казан мәдәният ин-тын тәмамлый (1989). 1992–95 елларда «Казан» милли мәдәният үзәге ансамбле солисты, 1996 дан «Аваз» җыр студиясе солисты. Б. репертуарын халык җырлары, Татарстан композиторлары әсәрләре, үзе язган көйләр һәм текстлар: «Теләк», «Әнкәй-эткәй» һ.б. тәшкил итә. Ялгыз башкаручы буларак һәм З.Билалова (Фәрхетдинова) б-н дуэт чыгышлары ясый. Еш концертлар куя, аудио- һәм видеодисклар яздыра. «Татар эстрадасы-88», «Татар җыры-91» конкурслары лауреаты.

**БИЛЯ́ЛОВ** (Билалов) Мөнир Шәрәфетдин улы (27.2.1928, Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны, Шубино а. — 29.10.1980, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (1973), ТАССРның атказ. табибе (1978). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Татарстанның Кузнечиха р-ны санэпидстанциясе баш табибе булып эшли, 1955 елдан шул ук районның сәламәтлек саклау бүлеге мөдире, 1957 дән баш табибнең дәвалау эшләре буенча урынбасары. 1958 дән Дөбъяз үзәк район хастаханәсе баш табибе. 1961 дән Казан ГИДУВында: нерв авырулары клиникасында, 1978–80 дә ректор. Хезмәтләре эндокринология өлкәсенә карый (кайбер диэнцефаль синдромнар очрагында бөер өсте бизе тышчасының функциясе үзгәрүне өйрәнә, дәвалау ысулларын тәкъдим итә). Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

**БИЧА́РИНА** Елена Исмәгыйль кызы (12.4.1951, Подберезье р-ны Иске Корбаш а.), җырчы, ТРның халык артисты (2011). Казан музыка уч-щесен тәмамлый (1985). 1975–92 елларда ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең хор төркеме солисты. Җырчы репертуарының төп өлешен татар халык җырлары һәм Татарстан композиторлары С.Садыйкова, А.Монасыйпов, Р.Яхин һ.б.ның вокаль әсәрләре тәшкил итә. Борынгы татар көйләрен зур осталык б-н башкара; шуларның берсе — «Чатырлар» — халык арасында аерым популярлык казана. 1990 елларда респ-ка телевидениесендә «Борынгы татар халык җырлары» тапшырулар циклын алып бара. Керәшен татарларның җыр мирасын саклауга һәм популярлаштыруга зур өлеш кертә. ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле составында дөньяның күп кенә илләрендә (Венгрия, Германия, Италия, Франция, Гыйрак, Төркия, Япония, Африка илләре һ.б.) гастрольләрдә була, ялгыз башкаручы сыйфатында концерт эшчәнлеге алып бара.

**БЛАШКО́ВА** Светлана Львовна (1.6.1967, Казан), терапевт-стоматолог, мед. фән. д-ры (2011). Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1989), шунда ук терапевтик стомат. кафедрасында эшли, каф. мөдире (2011 дән). Хезмәтләре хроник генерализацияләнгән пародонтитның патогенетик сыйфаты критерияләрен эшләүгә карый.

**БЛОХИНА́** Марина Владимировна (2.9.1977, Казан), шәфкать туташы хезмәте белгечлеге буенча менеджер, мед. фән. д-ры (2008). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (2001), шунда ук эшли. Хезмәтләре сәламәтлек саклау учреждениеләрендә персонал б-н идарә итү системасын фәнни-методик яктан тәэмин итү өлкәсенә карый.

**БОГДА́НОВ** Евгений Иванович (30.11.1938, Яшел Үзән ш. — 30.7.2007, Алабуга ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1962), Алабуга пед. ин-тында эшли, 1983 елдан теоретик физика каф. мөдире. Хезмәтләре оптик резонансның квант теориясенә карый. Азаклы үлчәмле һәм азаксыз үлчәмле динамик системаларның эволюциясе ярдәмендә модельләштерү процессларына нигезләп классик һәм квант физикасы объектларын тикшерүнең яңа юлларын эшли. Медаль б-н бүләкләнә.

**БОГРЯКО́В** Вячеслав Александрович (23.5.1960, Оренбург өлкәсенең Сарыкташ р-ны Фёдоровка а.), слесарь, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Новотроицк төзелеш техникумын (Оренбург өлкәсе, 1979) тәмамлый. 1977–85 елларда Оренбург өлкәсендәге пр-тиеләрдә эшли. 1985 тән «Алабуга автомобильләр заводы ЖБ» АҖнең Станок-инструментлар з-дында. Дәүләт бүләге нефть һәм газ скважиналарын ремонтлау һәм үзләштерү максатында йөк күтәрүчәнлеге 50 һәм 80 *т* тәшкил иткән югары технологияле күтәргеч агрегатларны эшләүдә һәм җитештерүдә катнашканы өчен бирелә.

**БО́ЛОТОВ** Евгений Александрович (14.11.1870, Казан — 27.9.1922, Мәскәү), механика өлкәсе галиме, проф. (1907). Казан ун-тын тәмамлый (1892), Мәскәү ун-тының гамәли матем. кафедрасында эшли. 1900–14, 1921–22 елларда Мәскәү югары техник уч-щесенең теоретик механика кафедрасында. 1914–21 дә Казан ун-тында, механика каф. профессоры, ректор (1917–21). Хезмәтләре аналитик механика һәм гидромеханикага карый. Гауссның иң ким мәҗбүрләү принцыбын тикшерә, алга таба бу эше аның һәм Казан механиклары мәктәбе галимнәре (Н.Г.Четаев, М.Ш.Әминов һ.б.) тикшеренүләренең нигезен тәшкил итә.

**БОЛЬШАКО́В** Андрей Георгиевич (13.1.1970, Казан), политолог, сәясәт фән. д-ры (2010), проф. (2016). Казан ун-тын тәмамлый (1992). 1992–98 елларда Казан технол. ун-тының тарих һәм социол. кафедрасында, 1999 дан Казан ун-тында. 2011 дән конфликтология каф. мөдире. ТР Президенты каршындагы милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча советның милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә низаглы вазгыятьләрне күзәтү һәм хәл итү комиссиясе әгъзасы. Хезмәтләре хәрби низаглар һәм сугышлар, конфликт һәм тынычлык, төбәкләрдәге сәяси низагларны, этноконфессиональ низаглар һәм социаль киеренкелекне, экстремизмны һәм террорчылыкны гражданлык кысаларында кисәтү мәсьәләләренә карый.

**БОЛЬШАКО́ВА** Земфира Максут кызы (12.04.1960, Чиләбе өлкәсенең Сатка ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2000), проф. (2000). Чиләбе ун-тын тәмамлый (1982). 1991 елдан Урал тимер юл транспорты инженерлары электромеханика ин-тының Чиләбе ф-лында укытучы. 1993 тән Чиләбе пед ин-тында, гомуми һәм махсус пед. һәм психол. каф. мөдире (2000 нән).

**БОРҺА́НОВ** Рафис Тимерхан улы (17.8.1961, Мөслим р-ны Мөслим а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. канд. (2000). Казан а.х. (1983) һәм Казан финанс-икътисад (1990) ин-тларын тәмамлый. 1985–87 елларда «Казанкомпрессормаш» ФҖБдә цех мастеры, ВЛКСМ ком-ты секретаре. 1987–89 да ВЛКСМның Казан шәһәр ком-ты 2 нче секретаре. 1989–96 да «Казанкомпрессормаш» АҖдә цех башлыгы урынбасары, цех башлыгы, икътисад бүлеге башлыгы, икътисад һәм финанс директоры. 1996–98 дә Казан шәһәре хакимияте башлыгының беренче урынбасары. 1998–99 да ТР икътисад һәм сәнәгать министрының беренче урынбасары. 1999–2005 тә Казан шәһәре Вахитов р-ны хакимияте башлыгы. 2005–07 дә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгының беренче урынбасары, 2007–10 да Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма ком-ты җитәкчесе. 2010–14 тә ТРның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры. 2014–17 дә ТР Дәүләт Советының икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек ком-ты рәисе. 2017 дән ТРның Премьер-министр урынбасары – ТР мәгариф һәм фән министры. Хезмәтләре Татарстанда көчеш икътисады шартларында финанс системасын дәүләт тарафыннан көйләү мәсьәләләренә карый. 2000–04, 2014–17 дә ТР Дәүләт Советы депутаты. Дуслык, Почёт орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**БОХАРА́ЕВА** Эля Әхмәт кызы (23.5.1956, Ленинград), биофизик, биол. фән. д-ры (2002), проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1978), Казан мед. ун-тының нормаль физиол., мед. һәм биол. физика кафедраларында эшли. 1997 елдан РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында. Хезмәтләре синаптик процессларның биофизикасы һәм физиологиясенә карый. Б. табигый нейромедиатор хәрәкәтен имитацияләүче матдәләрнең пресинаптик эффектларын тикшерә; кальций ионнарының нейросекреция процессы кинетикасы модуляциясендә төп роль уйнавын ачыклый.

**БО́ЧИНА** Татьяна Геннадьевна (11.1.1963, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2004), проф. (2008). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1985), шунда ук эшли, 2003 елдан чит тел буларак рус теле каф. мөдире, 2015 тән Рус теле һәм мәдәниятара багланышлар югары мәктәбе деканы. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының чит тел буларак рус теле, Россия тарихы һәм РФ законнары нигезләре буенча имтиханнар уздыруны методик яктан тәэмин итү комиссиясе әгъзасы. Хезмәтләре рус теле лексикографиясе, фразеологиясе һәм паремиологиясенә карый. Чит ил студентлары һәм стажёрлары өчен уку-укыту ярдәмлекләре, ш.у. рус теле дәреслекләре авторы.

**БРА́ЖНИК** Лариса Владимировна (1938, Чиләбе өлкәсенең Магнитогорск ш.), музыка белгече, сәнгать фән. д-ры (2003). ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993). Магнитогорск музыка уч-щесен (1956), Казан консерваториясен (1961) тәмамлый. 1961–64 елларда Казан консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбендә, 1964–74 тә Казан музыка уч-щесендә укыта. 1974 тән Казан консерваториясендә: музыка теориясе каф. мөдире (1985–87), фән эшләре буенча проректор (1989–98), музыка тарихы каф. мөдире (2000–03), музыка теориясе һәм тарихы каф. мөдире (2003–09).

**БУГАЕ́НКО** Адольф Георгиевич (31.3.1939, Ростов-Дон ш. — 1.5.2011, Казан), оптика-электрон приборлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2005), проф. (2008). ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1999). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), шунда ук эшли, проректор (1979–82). 1971 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1982 дән ГИПО ФҖБдә: лаб. башлыгы (1984–82), бүлек башлыгы (1987–2007). Бер үк вакытта, 2006 дан, Казан техник ун-тының оптика-электрон системалары каф. профессоры. Хезмәтләре тепловизорлы приборлар булдыруга карый. Б. җитәкчелегендә тепловизорлы техника сыйфатламаларына бәяләмә бирү өчен контроль-үлчәү җиһазлары эшләнә. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медаль б-н бүләкләнә.

**БУЛА́ТОВ** Айдар Нәфис улы (2.6.1979, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2011). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (2000). 2002–07, 2010–11 елларда Казан финанс-икътисад ин-тында, 2011–12 дә, 2013 тән Казан ун-тында укыта. Хезмәтләре корпоратив идарә, эшмәкәрлек үсеше б-н идарә итү мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга патенты бар.

**БУЛА́ТОВ** Марат Фатыйх улы (26.7.1967, Әстерхан өлкәсенең Нариманов р-ны Солянка а.), физик, физика-матем. фән. д-ры (2005). Әстерхан пед. ин-тын (1991), Дон технол. ин-тын (Ростов-Дон ш., 2007), Әстерхан ун-тын (2011), Кларк ун-тын (Бостон, АКШ; 2011) тәмамлый. 1991 елдан Әстерхан пед. ин-тында (хәзер Әстерхан ун-ты) эшли, физика һәм электроника ф-ты деканы (2001–04), Физика-матем. инновацион үсеш ин-ты директоры (2004–10), электроника һәм техник физика каф. мөдире (2008–13), бер үк вакытта, 2010–13 тә, ун-т проректоры. 2013 тән Сирәк металл сәнәгате дәүләт фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тының «Гиредмет» АҖ (Мәскәү) директоры урынбасары, директор. Хезмәтләре оксид магнит материалларның структур, магнитик, электр үзлекләрен тикшерүгә карый. Графен катлауларны пар фазасыннан химик утырту алымы б-н синтезлау технологиясен эшли.

**БУЛА́ТОВ** Сергей Александрович (28.11.1961, Әлмәт р-ны Рус Акташы а.), хирург, мед. фән. д-ры (2000). Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1984), шунда ук, 1 нче хирургия кафедрасында эшли, каф. профессоры (2005 тән). Хезмәтләре тыныч вакыттагы һәлакәт очракларында хирургия ярдәме күрсәтүгә карый.

**БУЛАШО́ВА** Ольга Васильевна (21.2.1955, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (2004), проф. (2011), ТРның атказ. табибе (1997). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Казан шәһәре 7 нче клиник хастаханәсендә участок табибе, 1883–85 елларда ТР Эчке эшләр министрлыгы госпиталенең терапия бүлеге башлыгы, 1985–88 дә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы баш терапевты. 1988–99 да Казан шәһәре күппрофильле 7 нче хастаханәсенең дәвалау мәсьәләләре буенча баш табиб урынбасары. Бер үк вакытта, 1988 дән, Казан мед. ин-тының пропедевтика һәм эчке авырулар бүлеге кафедрасында. 1999–2015 тә Төбәкара клиник диагностика үзәгенең (Казан) дәвалау мәсьәләләре буенча баш табиб урынбасары. Бер үк вакытта, 2004 тән, ТР Профсоюзлар федерациясенең курортларны үстерү бүлеге башлыгы урынбасары. Фәнни тикшеренүләре йөрәк-кан тамырлары авыруларын дәвалау һәм кисәтүгә, аеруча хроник йөрәк зәгыйфьлегенең башка авырулар (хроник обструктив үпкә авырулары, хроник бөер авырулары, хроник баш мие ишемиясе) б-н бергә килү очракларын өйрәнүгә карый. ТР Терапевтлар фәнни җәмгыяте идарәсе, ТР Кардиологлар җәмгыяте, Россия йөрәк зәгыйфьлеге белгечләре җәмгыяте әгъзасы. Медаль б-н бүләкләнә.

**БУРМИ́СТРОВ** Михаил Владимирович (1.6.1971, Казан), хирург-онколог, мед. фән. д-ры (2006). Проф. Е.И.Сигал шәкерте. Казан мед. ун-тын тәмамлый (1996), 1997 елдан Казан мед. академиясенең онкология һәм хирургия кафедрасында эшли. 2000 нән Респ-ка онкология клиник диспансерының үңәч хирургиясе бүлегендә. Хезмәтләре хирургия өлкәсенә: онкология авыруларына диагноз кую һәм авыруны дәвалау, дәвалауда эндохирургик алымнар кертүгә карый. Хирургия алымнарын кулланудан соң катлауланулары кисәтү ысулларын эшли. Уйлап табуга 2 патенты бар.

**БУРУНДУКО́ВСКАЯ** Елена Викторовна (26.10.1960, Казан), органчы, клавесинда уйнаучы, музыка белгече, педагог, сәнгать белеме д-ры (2009). Казан консерваториясен Э.Монасзонда һәм Р.Еникиевта фортепиано һәм Р.Абдуллинда орган класслары буенча тәмамлаганнан соң (1983), шунда ук укыта. Россиядә һәм чит илләрдә концерт эшчәнлеге алып бара. Италиядә халыкара орган фестивальләрендә (Брешия, Кремона, 1992, 1995), Швейцариядәге Бах академиясе (Порронтрюи, 1993, 1994), Австрия Барокко академиясе (Гмунден, 2008) һ.б. эшләрендә катнаша. Фәнни кызыксынулар өлкәсе — барокко чоры музыкасы һәм аны клавишлы инструментларда башкару үзенчәлекләре, «Италиянең органлы-клавирлы мәдәнияте (XVI йөз ахыры – XVII йөзнең беренче яртысы)» («Органно-клавирная культура Италии (конец XVI – первая половина XVII века)», 2007) монографиясе, «Үз тормышым дәреслеген язам» («Учебник жизни собственной пишу», 2004) шигъри китабы авторы. Язучылар берлеге әгъзасы (1996). М.Горький исем. әдәби бүләк лауреаты (Казан, 2006).

**БУТЕ́НКО** Юрий Иванович (7.8.1935, Украина ССРның Харьков ш.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2004), проф. (2005). 1959 елда Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1962–65 тә Казан авиация ин-тының материаллар каршылыгы кафедрасында, 1965 тән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, материаллар каршылыгы каф. профессоры (2002 дән). Хезмәтләре пластиналар һәм сүрүләр теориясе тигезләмәләрен төзү һәм чишү алымнарына, күп катламлы кендекләр һәм пластиналарны хисаплау өчен «төгәл» алымнар төзүгә карый. Пластиналар һәм сүрүләрне хисаплау өчен аныкланган модельләр төзү алымын, бер катламлы һәм күп катламлы кендек һәм пластиналарны хисаплау өчен нәклассик модельләрне төзүнең асимптотик алымнарын тәкъдим итә.

**БУХА́РОВ** Сергей Владимирович (26.3.1956, Саратов ш.), химик-органик, химия фән. д-ры (2004), проф. (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук эшли. 1988 елдан Казан технол. ун-тында, Эластомерлар эшләү үзәгенең органик кушылмалар синтезы лаб-ясе мөдире (1992–2000), төп органик синтез технологиясе каф. профессоры (2004 тән). Хезмәтләре диен синтезы, фенол стабилизаторлар химиясе һәм технологиясенә карый. Зәгыйфь N-, C-, S-нуклеофилларны бензилирлау алымнарын; феноламин стабилизаторлар булдыру максатында ароматик аминнарны бензилирлауның каталитик ысулын тәкъдим итә. Полимерларның полифункциональ стабилизаторлары тәҗрибә партияләрен синтезлау алымнарын эшли; аларны булдыра. Уйлап табуга 70 авторлык таныклыгы бар.

**БЫСТРО́ВА** Марина Владимировна (4.5.1957, Алексеев р-ны Алексеев а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2010). Казан театр уч-щесен тәмамлый (1983). Талды-Курган, Күкчәтау, Актүбә (Казакъстан) өлкә драма театрларында эшли, 1989 елдан Бөгелмә рус драма театрында. Труппаның әйдәп баручы актрисаларыннан берсе, театр репертуарындагы күп кенә баш рольләрне башкара. Б. тудырган образлар табигый, тормышчан булулары б-н аерылып тора, актриса героиняларының рухи дөньясын бөтен тулылыгында ачарга омтыла: Жанетта («Кара кәләш», Ж.Ануй), Жозефина («Наполеон Беренче», Ф.Брукнер), Онка («Бөкре», С.Мрожек), Мәхмәнәбану («Мәхәббәт турында риваять», Н.Хикмәт), Ольга («Бертуган кызлар», Л.Н.Разумовская), Прыся («Чәлдерүче», В.И.Ольшанский).

**ВАЙССБЕ́ККЕР** Ольга Петровна (3.9.1972, БАССРның Салават ш.), музыкант, оркестр солисты, ТРның халык артисты (2018). Казан консерваториясенең инструменталь башкару бүлеген (балалайка) тәмамлый (1997). 1994 елдан ТРның Дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры солисты. Халыкара (В.Андреев исем., С.-Петербург, 2005; «Төньяк кубогы», Череповец, 2007), бөтенроссия («Урал кубогы», Магнитогорск) халык музыка уен коралларында башкаручылар конкурслары лауреаты, дипломанты. Репертуарында — төрле юнәлештәге 100 дән артык әсәр (чит ил һәм рус классикасы, татар халык көйләре, хәзерге заман композиторлары, ш.у. З.Хәбибуллин, С.Сәйдәшев, Ә.Бакиров, А.Ключарёв, Р.Яхин һ.б.ның әсәрләре, эшкәртмәләре).

**ВАЛО́ВСКИЙ** Владимир Михайлович (19.1.1947, Бөгелмә ш.), нефтьче, техник фән. д-ры (1997). Мәскәү югары техник уч-щесен тәмамлаганнан соң (1971), ТатНИПИнефтьтә эшли, директор (1999 елдан). Хезмәтләре нефть скважиналарын куркынычсыз үзләштерү, штангалы скважина насослары йөрткечләре (шүргечләре) өчен технологияләр һәм җиһазлар комплексларын булдыруга карый. Дөнья нефть гыйлемендә беренче буларак яңа йөрткечләр (шүргечләр) теориясен эшли, аларны булдыра һәм гамәлгә кертә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ВАЛО́ВСКИЙ** Константин Владимирович (9.4.1971, Томск ш.), нефтьче, техник фән. канд. (2000), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Петербург ун-тын тәмамлый (1994). 1999 елдан ТатНИПИнефтьтә эшли, нефть чыгару техникасы һәм технологиясе лаб-ясе мөдире (2001дән). Дәүләт бүләге авыр чыгарылулы нефть запасларын чыгару нәтиҗәлелеген арттыру максатында яңа технологияләр һәм җиһазлар комплексын эшләүдә һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ВАНЬКО́В** Юрий Витальевич (24.8.1966, Пермь өлкәсенең Юрла р-ны Юрла а.), физик, техник фән. д-ры (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1990), Казан югары артиллерия уч-щесендә эшли. 2002 елдан Казан энергетика ун-тында, сәнәгый җылылык энергетикасы (2004–07), сәнәгый җылылык энергетикасы корылмалары һәм җылы б-н тәэмин итү системалары (2007 дән) кафедралары мөдире, проф. (2010 нан), бер үк вакытта проректор (2008–10). Хезмәтләре түбән ешлыклы акустик контроль алымнары өлкәсенә карый. Эшләнмәләрнең техник халәтләрен аларның тибрәнеш күрсәткечләре буенча контрольдә тоту алымнарын һәм җайланмаларын тәкъдим итә. Уйлап табуга 22 патенты һәм авторлык таныклыгы бар.

**ВАРВА́РИН** Владимир Николаевич (14.2.1843, Рязань — 10.2.1915, Петроград), хокук белгече, сенатор (1897), хакыйкый яшерен советник (1911). Чыгышы б-н дворяннардан. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1866). 1866–68 елларда Рязань губернасы Спас округында мәхкәмә тикшерүчесе, 1868–70 тә җәмәгать судьясы. 1870–72 дә Рязань округы мәхкәмәсе прокуроры иптәше (урынбасары), 1973–74 тә прокуроры. 1872–73 тә Гродно губернасы прокуроры. 1874–76 да Казан округы мәхкәмәсе прокуроры. 1876–78 дә Варшава мәхкәмә палатасы прокуроры иптәше. 1878–82 дә Петраковск округы мәхкәмәсе рәисе. 1883–94 тә Казан мәх-

кәмә палатасы прокуроры. 1894–97 Петербург мәхкәмә палатасы департаменты рәисе. 1897–1911 дә җинаять эшләре кассациясе департаментында, 1911 дән Сенатның гомуми җыенында. Казан хокук җәмгыятен оештыручыларның берсе һәм рәисе (1888–94). Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә.

**ВАСИ́ЛОВА** Нурания Зөфәр кызы (29.03.1959, Свердловск өлкәсенең Красноуфимск р-ны Урта Баяк а.), орлыкчылык белгече, а.х. фән. канд. (2003). ТРның атказ. агрономы (1911), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2015). Казан ун-тын тәмамлый (1983). Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының язгы бөртекле, бөртекле-кузаклы һәм ярма культуралары бүлегендә әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Язгы бодайның «Әмир», «Казанская юбилейная», «Экада 66», «Экада 109», «Экада 97», «Экада 113», «Йолдыз», «Иделле», «Хәят» сортлары авторы һәм автордашы. Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касы шартларына яраклаштырылган бөртекле культураларның көндәшлеккә сәләтле сортларын булдырганы һәм гамәлгә кертkәне өчен бирелә.

**ВАСИ́ЛЬЕВ** Геннадий Иванович (13.4.1949, Бондюг штп, хәзер Менделеев ш.), физик, химия фән. канд. (1998), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1975). 1976 елдан Казан язу җайланмалары з-дында гражданнар оборонасы штабы башлыгы урынбасары. 1979 дан Казан ун-тында (бүленеп, 1995–98 дә Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лы лаб-ясе мөдире). Хезмәтләре гетерогенлы мохиттә молекуляр хәрәкәтләрне тикшерүгә карый. Дәүләт бүләге катлаулы молекуляр системаларның төзелешен һәм динамикасын өйрәнүдә градиентлы төш магнит резонансын үстерүдәге эшләр циклы өчен бирелә.

**ВАСЮ́ТИН** Евгений Зиновьевич (15.11.1952, Мари АССРның Таулы Мари р-ны Микряково а. — 18.6.2012, Казан), хокук белгече, Мари Респ-касының (2002), РФнең (2002) атказ. юристы. Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1979–82 елларда Мари АССР Юстиция министрлыгында өлкән консультант. 1982–86 да Йошкар-Ола шәһәренең Ленин р-ны халык мәхкәмәсенең халык судьясы. 1986–88 дә «Лесмаш» (Мари АССР) з-дында юрисконсульт. 1988–89 да «Контакт» з-дында — бюро, 1989–90 да бүлек башлыгы. 1990–92 дә Мари АССР ЮС һәм аның Президиумы секретариатында консультант, бүлек башлыгы. 1992–95 тә Мари Респ-касы Югары арбитраж мәхкәмәсе, 1995–2003 тә Арбитраж мәхкәмәсе, 2003–07 дә Ульянов өлкәсе Арбитраж мәхкәмәсе рәисе. 2008 дән Идел буе округы Федераль арбитраж мәхкәмәсе рәисе (Казан). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ВАФИ́ЕВ** Равил Айса улы (27.5.1942, Тубыл ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2000). Кыргыз ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук эшли. 1987–89 елларда Әфганстан Халык-демократик партиясе ҮК Иҗтимагый фәннәр ин-тында (Кабул ш.): милли мәсьәләләр буенча киңәшче, рус теле укытучысы. 1989–91 дә Вунгтау шәһәрендә (Вьетнам) рус теле укыта. 1992–2001 дә Тубыл пед. ин-тында, татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире. 2002 дән Югра ун-тының (Ханты-Мансийск ш.) Югра халыклары тел, тарих һәм мәдәният ин-тында, гомуми тел белеме һәм уралистика каф. профессоры. Хезмәтләре социологиягә, икетеллелек проблемаларына, тюркологиягә, фин-угор телләре белеменә, лингводидактикага, рус һәм төрки телләрне чагыштырма өйрәнүгә карый. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2005), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2008).

**ВА́ФИН** Гадел Юныс улы (4.11.1973, Казан), терапевт, сәламәтлек саклау өлкәсе оештыручысы, мед. фән. канд. (2000), ТРның атказ. сәламәтлек саклау хезмәткәре (2013). Казан мед. ун-тын (1997), ТР Президенты каршындагы Дәүләт муниципаль идарә академиясен (2010) тәмамлый. 2001–07 елларда «Дрегер Медицинская техника» ҖЧҖнең төбәк идарәчесе. 2007–13 тә ТР сәламәтлек саклау министрлыгының беренче урынбасары, 2013–18 дә ТР сәламәтлек саклау министры. Бер үк вакытта Казан мед. ун-тының сәламәтлек саклау өлкәсе менеджменты каф. мөдире. 2018 дән «Медси» компанияләр төркеме директоры. Хезмәтләре мед.-социаль мәсьәләләрне хәл итүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ВАХИ́ТОВ** Рифкать Мөхәммәт улы (26.2.1938, Удмурт АССР, Ижевск ш.), нәкышьче, монументалист, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2005). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1959), Харьков сынлы сәнгать уч-щесен (1965) тәмамлый. 1970 елларда Ташкент шәһәрендә яши, Театр-сәнгать ин-тында укыта, җәмәгать биналарын монументаль-декоратив бизәү («Динамо» стадионы фасадларында керәчтән мозаика, «Ташкент-2» аэропорты, «Ләззәт» кафесы һ.б. фойеларына бизәк төшерү), нәкышь б-н шөгыльләнә. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1972). 1973–80 дә Чаллы шәһәрендә «Татарстан» кунакханәсе фойесындагы «Сабантуй» керәч рельефы, автомеханика техникумындагы «Комсомол тарихы», 3 нче мәктәптәге «Тынычлык» мозаика паннолары иҗат итә. 1984 тән Казанда. Жанрлы әсәрләр («Болгар җире турында риваять» триптихы, 1991; 5 картинадан торган «Татарнамә», 1995; «Моң», 1997; «Тукай дөньясы» полиптихы, 2006); портретлар («Рәхимҗан бабай», 1980; «Г.Исхакый», «Б.Урманче», икесе дә — 1989; «Олуг Мөхәммәд», 2006); татар һәм Шәрекъ мөселман сәнгате традицияләрендәге пейзажлар, натюрмортлар авторы.

**ВАҺА́ПОВ** Ядкәр Сәхап улы (15.10.1929, Бөгелмә кантоны Урмышлы а. – 2.3.1981, Төмән ш.), нефтьче-вышка монтажчысы, Соц. Хезмәт Герое (1971). Хезмәт эшчәнлеген туган авылында колхозчы буларак башлый. 1950–64 елларда (бүленеп) «Татбурнефть» (Лениногорск ш.) трестында эшли. 1953–58 дә «Бөгелмәнефтегазразведка» трестының вышкалар монтажлау конторасында. 1954–75 тә «Главтюменнефтегаз» ҖБдә (Төмән өлкәсенең Нижневартовск ш.). 1971–72 дә Ханты-Манси округы Советы депутаты. Герой исеме 8 нче бишьеллыкның (1966–70) нефть чыгару буенча план йөкләмәләрен үтәүдәге казанышлары һәм югары техник-икътисади күрсәткечләргә ирешүе өчен бирелә. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Урмышлы мәктәп музеенда В.ка экспозиция багышлана.

**ВАҺА́ПОВА** Гөлнара Рифат кызы (3.7.1964, Казан), эндокринолог, мед. фән. д-ры (2008). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), Казандагы 6 нчы шәһәр хастаханәсендә эшли, 1989 елдан тимер юлчылар хастаханәсендә. 1991 дән Казан мед. академиясендә, эндокринология каф. мөдире (2008 дән). Хезмәтләре аутоиммунлы тиреодитны өйрәнүгә, авыруларны рациональ дәвалау алымнары булдыруга карый.

**ВАЧА́ГИНА** Екатерина Константиновна (9.6.1960, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1984). 1985 елда Казан химия-технол. ин-тының химия технологиясе процесслары һәм аппаратлары каф. инженеры. 1986 дан Мәскәү энергетика ин-ты Казан ф-лында (2000 нән — Казан энергетика ун-тында): фәнни-тикшеренү бүлеге инженеры, фәнни хезмәткәре, сәнәгать җылылык энергетикасы каф. өлкән укытучысы, әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. 2004 тән РФА КГҮдә: энергетика бүлегенең сәнәгать җылылык энергетикасы лаб-ясе әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, Энергетика проблемалары тикшеренү үзәгенең җылылык физикасы тикшеренүләре лаб-ясе мөдире (2005 тән), җылылык физикасы һәм дулкынлы технологияләр лаб-ясе әйдәп баручы фәнни хезмәткәре (2015 тән), Энергетика һәм перспектив технологияләр ин-тының җылылык физикасы һәм дулкынлы технологияләр лаб-ясе әйдәп баручы фәнни хезмәткәре (2018 дән). Уйлап табуга 2 патенты бар. Фан-Тьен-Таннер реологик модельләренең параметрларын, интенсификаторлы гомофазалы полимеризацион реакторда гидродинамик һәм җылылык алмашу параметрларын, түгәрәк торба тибындагы гомофазалы полимеризацион реакторда агымның гидродинамик һәм җылылык алмашу характеристикаларының критик күрсәткечләрен исәпләү программалары автордашы. Хезмәтләре үзле һәм реологик катлаулы сыеклыклар агымында гидродинамика һәм җылылык алмашу, җылылык алмашу каналларында нәньютонча тирәлек агымы вакытында җылылык күчерү мәсьәләләрен аналитик һәм санча хәл итү мәсьәләләренә карый.

**ВӘЛИ́ЕВ** Дамир Хәмит улы (15.2.1975, Казан), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2010), проф. (2013). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1997), шунда ук эшли: 2000 елдан гражданнар хокукы һәм процессы кафедрасында, 2005 тән экология, хезмәт хокукы һәм процессы кафедрасында. Хезмәтләре граж-

данлык, арбитраж процессына, башкарма һәм третейский мәхкәмә эшләренә карый. Почёт ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ВӘЛИ́ЕВ** Рафаэль Миргасим улы (28.8.1955, Лениногорск р-ны Керкәле а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2011), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1996). Казан ун-тын (1977), ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте академиясен (2001), РФ Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте академиясен (2005) тәмамлый. 1977–2006 елларда ТР Мәдәният министрлыгында: министр урынбасары (1996 дан), министрның беренче урынбасары (2001 дән); бер үк вакытта, 1994 тән, Казан ун-ты доценты, профессоры (2007 дән). 2006–07 дә ТР Милли музее директоры урынбасары. 2007–18 дә Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты проректоры. 2018 дән Казан федераль ун-тының бөтендөнья мәдәни мирасы каф. мөдире; бер үк вакытта, 2019 дан, ун-тның Халыкара мөнәсәбәтләр ин-ты директоры урынбасары. Хезмәтләре Татарстанның, татар халкының тарихи-мәдәни мирасын саклау, реставрацияләү һәм популярлаштыруга; Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда нумизматикасына һәм товар-акча мөнәсәбәтләренә карый. 2000 нән мәгариф, фән һәм мәдәният мәсьәләләре буенча БМО эксперты. 1998–2000 дә Казан Кремлен Бөтендөнья мәдәни мирасы (ЮНЕСКО) объектлары исемлегенә кертү комиссиясе әгъзасы, 2016 дан Һәйкәлләрне һәм тарихи урыннарны саклау буенча халыкара советның (ICOMOS) Россия милли ком-ты вице-президенты. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ВӘЛИ́ЕВ** Рөстәм Шәрифулла улы (27.10.1961, Куйбышев ш., хәзер Самара ш. — 5.3.2014, Казан), баянчы, концертмейстр, ТРның халык артисты (2006), РФнең атказ. артисты (2013). Казан консерваториясен тәмамлый (1988). 1984–2014 елларда Татар филармониясендә. Концертмейстер буларак Татарстанның әйдәп баручы вокал сәнгате осталары (И.Шакиров, Ә.Авзалова, Х.Бигичев, З.Сәхәбиева, В.Гыйззәтуллина һ.б.) б-н чыгышлар ясый. Ф.Туишев исем. музыкант-башкаручылар (Казан, 1988), проф. гармунчылар (Казан, 1995); 8 нче «Россия оста гармунчыларының алтын унлыгы» фестивале (Уфа ш., 2005) конкурслары лауреаты. 2 нче бөтенроссия «Россия авазлары» халык җырлары телерадиоконкурсы дипломанты (Смоленск ш., 1994). Соло программалар б-н Россиядә һәм чит илләрдә гастрольләрдә була, телевидение һәм радиода чыгышлар ясый. Ялгыз башкаручы баянчы буларак, В.нең иҗатына югары профессиональлек, үзенчәлек хас. Репертуарын татар халык көйләре, татар композиторлары, дөнья классикасы әсәрләре тәшкил итә. «Зәлидә», «Сүнмәс дәрт», «Сандугач-күгәрчен» һ.б. халык көйләре эшкәртмәләре авторы.

**ВӘЛИ́ЕВА** Алсу Фоат кызы (30.3.1956, Омск ш.), социолингвист, социол. фән. д-ры (2004). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1978). 1978–83 елларда «Союзнефтехимпром» ФҖБдә тәрҗемәче. 1983–2010 да Татар гуманитар-пед. ун-тында чит телләр (ш.и. латин теле), гуманитар фәннәр циклы укытучысы, 2011 дән Казан ун-тының Филол. һәм мәдәниятара багланышлар ин-тында. Хезмәтләре полиэтник җәмгыятьтә (Идел буе респ-калары материалларында) телләр дисциплинасының теоретик-методологик һәм гамәли версияләрен анализлауга, телләр дисциплинасын социол. нигезләүгә карый.

**ВӘЛИ́ЕВА** Ильвера Фәрит кызы (17.7.1968, Бөгелмә ш.), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). Уфа нефть техник ун-тын тәмамлый (1993). ВНИИнефтьтә эшли (Бөгелмә), 1998 елдан ТатНИПИнефтьтә. 2005 тән ТР ФАдә: Янучан файдалы казылмаларны эзләү һәм үзләштерү мәсьәләләре фәнни-тикшеренү үзәгендә, Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре ин-тының геол. анализ лаб-ясе мөдире (2008 дән). Дәүләт бүләге нефть чыганакларын эзләү алымнары комплексын эшләп, ТРның көнбатыш өлешенең нефтьлелеге перспективасын бәяләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ВӘЛИ́ЕВА** Люция Гали кызы (15.5.1931, Башкортстан АССР, Янавыл р-ны Эткенә а.), музей хезмәткәре, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982, 1986). 1953–63 елларда ТАССР Дәүләт музеенда эшли. 1971 дән партия эшендә. 1978–87 дә ТАССР Дәүләт музее (1982 дән ТАССР Берләштерелгән дәүләт музее, 2001 дән ТР Милли музее) директоры. В. җитәкчелегендә музейның экспозицияләре яңартыла, матди базасы ныгытыла, аның ф-ллары — Казанда һәм Яңа Кырлай авылында Г.Тукай музейлары, Казанда М.Җәлил һәм Ш.Камал музей-фатирлары, А.М.Горькийның Казандагы әдәби музее, Яшел Үзән шәһәрендә Халык иҗаты һәм этнография музее, Чистайда өяз шәһәре музее, Печищида Я.Купала музее, Түбән Кама музее һ.б. булдырыла. «Үткән сәхифәләрне барлаганда» («Страницы прошлого листая», 2005) китабы авторы.

**ВӘЛИ́ЕВА** Фәридә Вәдүт кызы (5.7.1958, Казан), эндокринолог, мед. фән. д-ры (2005), проф. (2008), ТРның атказ. табибе (2014), РФ Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге бүләге лауреаты (2012). Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1981), шунда ук эндокрионология кафедрасында эшли, 2015 елдан каф. мөдире. Идел буе федераль округының штаттан тыш баш эндокринологы. Хезмәтләре диабет авыруына диагноз кую һәм авыруны фармакологик коррекцияләүгә карый. Россия эндокринологлар ассоциациясе идарәсе, ТР эндокринологлар ассоциациясе, Европа шикәр диабетын өйрәнүчеләр ассоциациясе әгъзасы.

**ВӘЛИ́ТОВ** Хәйдәр Зөфәр улы (17.9.1958, Куйбышев өлкәсенең Келәүле р-ны Иске Ярмәк а.), селекционер зоотехник, а.х. фән. д-ры (2012). Куйбышев а.х. ин-тын тәмамлый. 1981–84 елларда Куйбышев өлкәсе Келәүле район башкарма ком-ты а. х. идарәсе зоотехнигы. 1984–2001 дә Волжск р-ны Черновский с-зы селекционер зоотехнигы. 2001 дән Самара а.х. академиясендә. Хезмәтләре сөт терлекләре көтүен интенсив файдалану өчен сыерларның продуктлылык вакытын озайтуга карый.

**ВЕЛИ́ЧКО** Юрий Александрович (15.10.1927, Брянск өлкәсенең Севск ш.), химик-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1974), техник фән. канд. (1985). Мәскәү химия-технол. ин-тын тәмамлый (1953). 1943–44 елларда Белоруссия фронтының 8 нче штурмлау инженер-сапёр бригадасы рядовое. 1944–48 дә тимер юл узелы (Брянск) эшчесе, электр монтёры. 1953–56 да Пермь шәһәрендә оборона з-дында эшли. 1956 дан Казанда: «Союзхимпромпроект» ин-тында баш белгеч, бүлек башлыгы, баш инженер (1986 га кадәр), Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. башлыгы, сектор башлыгы (1995 кә кадәр). Хезмәтләре махсус химия өлкәсендә технологияләр эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә карый. Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

**ВЕРЕЩА́ГИНА** Яна Александровна (23.1.1966, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1988), Казан технол. ун-тында эшли, гомуми химик технол. каф. профессоры (2005 елдан), бер үк вакытта, 1998 дән, Казан ун-тының Химия ин-тында элементорганик кушылмалар фәнни-тикшеренү лаб-ясендә. Хезмәтләре элементорганик кушылмаларны синтезлау һәм аларның структурасын тикшерүгә карый. Полифункциональ нитроэтеннарга систематик конформацион анализ ясый, фосфорланган нитровинилиндолларның төзелешен билгели; ациклик, гетероциклик фосфор һәм кремний кушылмаларның конформацияләрен ачыклый. В. тикшеренүләре элек өйрәнелмәгән фосфорорганик кушылмалар хакында бер төркем теоретик гомумиләштерүләр ясарга, аларның төзелешенә һәм үзара электроник тәэсирләшүләренә караган фаразлауга мөмкинлек тудыра.

**ВЕ́ХОВ** Николай Кузьмич (15.5.1887, Саратов губернасының Вольск ш. — 6.11.1956, Мәскәү), селекционер-дендролог, а.х. фән. д-ры (1935), проф. (1947). Мәскәү а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1912), шунда ук эшли. 1919 елдан Казан а.х. һәм урманчылык ин-тында, бер үк вакытта Раифа тәҗрибә-укыту урман хуҗалыгы мөдире. 1925–32 дә Урман-дала тәҗрибә-селекция станциясе директоры (Тула ш.). 1933 тән Бөтенсоюз агроурманмелиорация фәнни-тикшеренү ин-тында хакимият-хуҗалык эшендә. Хезмәтләре бакчачылыкта һәм яшелләндерүдә файдаланыла торган декоратив үсемлекләр булдыруга карый. Идел-Кама тыюлыгында дендрарий оештыручыларның берсе, матур чәчәк ата торган бакча ясмине, канәферләр, күпьеллык декоратив үсентеләр

сортларын барлыкка китерүче. Ленин ордены б-н бүләкләнә. Идел-Кама тыюлыгындагы (Яшел Үзән р-ны) Садовый посёлогы урамына В. исеме бирелә.

**ВЛАДИ́МИРОВА** Ирина Сильвестровна (15.10.1949, Белоруссия ССР, Брест ш.), биотехнолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), техник фән. канд. (1990). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), ГИПОда эшли. 1984 елдан Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре микробиол. сәнәгать өчен ресурс саклаучан интенсив технологияләр эшләүгә карый. В. аэроб ферментлы процесска кислород ташучы нәионоген өслекчә-актив матдәләрне өстәгәндә газ фазасыннан сыеклыкка кислород килүе интенсивлашуын, максатлы продуктның чыгышы артуын, технол. цикл озынлыгы кыскаруын, чимал һәм энергетик ресурслар чыгымы азаюын билгели. Рибоксин (мед. препаратлар з-ды, Пенза ш.), лизин (биохимия з-ды, Латвиянең Ливаны ш.) кебек дару препаратлары җитештерүнең интенсив технологияләрен эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнаша. Дәүләт бүләге чүпрә генерациясенең аэроб технологиясен спирт җитештерү процессына кертү алымын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2001).

**ВО́ЛГИНА** Светлана Яковлевна (18.6.1958, Алма-Ата ш.), педиатр, мед. фән. д-ры (2000), проф. (2001). Казан мед. ун-тын тәмамлаганнан соң (1982), Мурманск өлкә хастаханәсендә эшли. 1983 елдан Казанда: 1 нче шәһәр балалар клиник хастаханәсендә мәктәпкәчә яшьтәге балалар табибе, 1984 тән 2 нче шәһәр балалар клиник хастаханәсенең баш табибе урынбасары, 1987 дән Казан ГИДУВында клиник ординатор, 1989 дан Казан мед. ин-тының поликлиника педиатриясе каф. ассистенты, 1994 тән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка гаиләне, аналар һәм балалар сәламәтлеген саклау үзәгендә фәнни хезмәткәр, өлкән фәнни хезмәткәр, педиатрия бүлеге мөдире, 2000 нән «МедСоцЭконом» респ-ка үзәге баш белгече, 2001 дән Казан мед. ун-тының поликлиника педиатриясе каф. профессоры, 2006 дан Казан ГИДУВының перинатология (педиатрия һәм неонатология) каф. профессоры, 2010 нан Казан мед ин-тының госпиталь педиатриясе каф. профессоры. Фәнни тикшеренүләре педиатрия, гастроэнтерология, социаль педиатрия, психологиягә һәм сирәк авыруларны дәвалауга карый. Уйлап табуга 2 патенты бар.

**ВО́ЛКОВ** Игорь Евгеньевич (26.5.1937, Казан — 24.8.2011, шунда ук), а.х.н механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2007), ТРның атказ. а.х. механизаторы (1992). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), 21 нче һөнәри-техник уч-щедә эшли. 1963 елдан Казан а.х. ин-тының (1995 тән Казан а.х. академиясе, 2006 дан Казан аграр ун-ты) а.х. җитештерүен электрлаштыру һәм терлекчелекне механикалаштыру кафедрасында, каф. профессоры (2001 дән). Хезмәтләре терлекчелектә механикалаштыру чаралары кулланунның нәтиҗәлелеген арттыруга карый. Саву процессының энергияне янга калдырулы технологияләрен, саву җайланмалары өчен вакуумлы насос күрсәткечләрен исәпләү ысулларын тәкъдим итә (ТРның а.х. пр-тиеләре һәм хуҗалыкларында кулланышка кертелә). Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**ВОЛОДЮ́ХИН** Михаил Юрьевич (1.12.1974, Казан), табиб рентгенолог, мед. фән. канд. (2005), ТРның атказ. табибе (2018), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан мед. ун-тын тәмамлый (1997). 2000 елдан Төбәкара клиник диагностика үзәгенең диагноз кую һәм дәвалауның рентген-хирургия ысуллары бүлегендә, 2013 тән бүлек мөдире. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының рентгенэндоваскуляр диагностика һәм дәвалау буенча штаттан тыш баш белгече (2014 тән). 2006 да Берн шәһәрендә (Швейцария) стажировка уза. Хезмәтләре магнит резонансы ангиографиясенә, рентгенэндоваскуляр диагноз кую һәм дәвалауга карый. Уйлап табуга 2 патенты бар. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында баш мие кан әйләнеше кискен бозылган авыруларга медицина ярдәме күрсәтү» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ВОРО́НИН** Евгений Константинович (22.10.1955, Свердловск өлкәсенең Гари р-ны Аганово пос.), химик-технолог, техник фән. канд. (1983), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), «Казан фотоматериаллар институты» АҖдә эшли, 2003 елдан «Ласкрафт» АҖ ген. директоры. Хезмәтләре химик производстволар (нечкә органик синтез продуктларын киптерү, фильтрлау, ректификацияләү) процессларын һәм аппаратларын эшләүгә карый. Дәүләт бүләге углеводород чималын күкертле кушылмалардан арындыру максатында фталоцианин катализаторларын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ВО́СТРИКОВ** Ядкәр Шакир улы (5.1.1945, Пенза өлкәсенең Городище р-ны Урта Әләзән а.), хирург, мед. фән. д-ры (1998). Саратов мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), 1 нче клиник хастаханәдә эшли (Саратов ш.). 1972–74 елларда һәм 1982 дән Саратов мед. ин-тының госпиталь хирургиясе кафедрасында. 1974–82 дә Саратов юл клиник хастаханәсендә. Хезмәтләре хирургиягә: диагностикага, аортаның һәм аорта-янбаш сегментының атеросклеротик зарарланулары бергә кушылган авыруларны дәвалауга карый.

**ГАБДЕЛХА́КОВА** Айсылу Рәдиф кызы (12.3.1967, Казан), китап белеме һәм әдәбият галиме, тарихчы, филол. фән. канд. (1998), тарих фән. д-ры (2011). Казан мәдәният ин-тын тәмамлаганнан соң (1988), шунда ук эшли, библиография каф. мөдире (2002 елдан), мәгълүмати-библиографик ресурслар каф. доценты (2003 тән), мәгълүмати-документ коммуникацияләре ф-ты деканы (2012 дән), китапханә белеме, библиография белеме һәм китап белеме каф. профессоры (2016 дан). Хезмәтләре татар балалар китабы тарихы, милли китап бастыру эше, библиографик, нәшрият эшчәнлеге, китапханә өчен кадрлар әзерләү мәсьәләләренә карый.

**ГАБДЕЛХА́КОВА** Ләйсән Равил кызы (25.9.1954, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2008). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук эшли, 2008–13 елларда рус теле тарихы һәм славян тел белеме каф. мөдире. Хезмәтләре рус әдәби теле тарихына һәм тарихи грамматикага карый. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2010).

**ГАБДРАХМА́НОВ** (Абрахманов) Илдус Илгизәр улы (27.5.1967, Апас р-ны Апас а.), драма актёры, режиссёр, хореограф. ТРның халык артисты (2014). М.С.Щепкин исем. югары театр уч-щесен тәмамлый (1988, Мәскәү). 1990 елдан Татар акад. театрында эшли. Романтик пландагы актёр. Бию остасы, сәхнә пластикасына ия. Театр сәхнәсендә тормышчан, кабатланмас, тирән психологизм б-н сугарылган драматик һәм үзенчәлекле комик образлар тудыра: Альдемаро («Биюче», Лопе де Вега), Сильвио («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони), Мансур, Илгизәр, Шүр-Шүр, Микуш, Алмаз, Бәдретдин, Шәкүр («Әлдермештән Әлмәндәр», «Илгизәр+Вера», «Җанкисәккәем», «Гөргөри кияүләре», «Шулай булды шул», «Мулла» («Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге, 2013), «Диләфрүз-Remake», Т.Миңнуллин), Тукай, Фәридун («Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре», «Баскетболист», М.Гыйләҗев), Ромео («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир), Севрюгин («Телсез Күке», З.Хәким), Ринат («GO! Баламишкин», Ф.Бүләков), Дәүләтов («Үлеп яратты», Р.Зәйдулла), Сәхипгәрәй («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Ратмир Закиевский («Ак калфагым төшердем кулдан...», И.Юзеев), Руфин («Хафалы биюләр», С.Юзеев), Сәяр Рәмиев («Бию пәрие», И.Зәйниев) һ.б. Режиссёр буларак «Кәҗә, Сарык һ.б.» (И.Зәйниев) спектаклен сәхнәгә куя. «Кара чикмән» (Г.Хугаев) спектакленең хореограф-репетиторы. Россия күләмендә төшерелгән нәфис фильмнардагы рольләре: Тушмон («Алангасар шәүләсе» — «Тень Алангасара», реж. А.Черниенко, 1994), Ефрейтор Каюмов («Ыргым» — «Прорыв», реж. В.Лукин, 2006). 11 нче Халыкара мөселман киносы фестиваленең «Кыска метражлы фильмда иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә җиңүче («Дүрт хатын» — «Хлопнул дверью и ушёл», реж. С.Юзеев; Ир роле өчен). ТР Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1995). Медаль б-н бүләкләнә.

**ГАБДРӘШИ́ТОВ** (Абдрәшитов) Равил Рәфкать улы (28.04.1949, Троицк ш.), хакимият-хуҗалык җитәкчесе. Чиләбе политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), Златоуст машина төзү, Троицк станоклар төзү (1980 елдан) з-дларында эшли. 1987 дән Троицк

шәһәр башкарма ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары. 1990–91 дә «Троицк май комбинаты» ААҖ ген. директоры урынбасары, 1996–99 да ген. директор. 1991–96 да Троицк шәһәре хакимияте башлыгы, 1996–2000 дә Чиләбе өлкәсенең Законнар чыгару җыены депутаты, 2005–2009 да Троицк шәһәре хакимияте башлыгы урынбасары.

**ГАБИДУ́ЛЛИНА** Зөлфия Рәүхәт кызы (22.11.1965, Казакъстан ССР, Жамбул өлкәсе Жамбул ш.), паралимпияче спортчы (йөзүче), йөзү буенча халыкара класслы спорт остасы (2011). Бала вакытында 1 нче төркем инвалидлыкка дучар була (аяклары параличлана). Спорт б-н 1990 елда шөгыльләнә башлый, коляскалы спортчылар узышларында катнашып, Казакъстан Спартакиадасында 2 алтын медаль яулый (1994). 1998 дән йөзүгә күчә. Казакъстан Респ-касының атказ. тренеры С.Е.Бейсембаев кул астында шөгыльләнә. 2008 дә респ-каның паралимпиячеләр җыелма командасына чакырыла. Казакъстан Респ-касының паралимпиячеләр җыелма командасы капитаны. Күптапкырлар Казакъстан Респ-касы чемпионы була. Казакъстан Респ-касының Паралимпия уеннары (2007, 2011, 2015), инвалид спортчыларның респ-ка Спартакиадасы (2013), Шарҗә (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, 2011), Шеффилд (Бөекбритания, 2012), Монреаль (Канада, 2013), Стадсканал (Нидерланд, 2013), Щецин (Польша, 2014), Инчхон (Корея, 2014), Алькоркон (Испания, 2015), Сан-Пауло (Бразилия, 2015), Сочи (Россия, 2015), Эйндховен (Нидерланд, 2016), Фуншал (Португалия, 2016), Берлин (Германия, 2016) шәһәрләрендә уздырылган халыкара ярышларның җиңүчесе һәм призёры. Спортчының 2016 да Рио-де-Жанейро шәһәрендә (Бразилия) узган Җәйге Паралимпия уеннарында дөнья һәм паралимпия рекорды күрсәтеп яулаган алтын медале — Казакъстан паралимпия спорты тарихында беренче алтын медаль. Г. — 11 тапкыр дөнья чемпионы, дөньяның иң көчле сигез йөзүче арасына керә. «Дос Тараз» инвалидлар җәмгыяте әгъзасы. Шәхси эшмәкәрлек б-н шөгыльләнә.

**ГАБИДУ́ЛЛИНА** Рушания Исмәгыйль кызы (9.7.1967, Биектау р-ны Усад а.), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (2004). Казан мед. ун-тын тәмамлаганнан соң (1991), шунда ук 2 нче акушерлык һәм гинекол. кафедрасында эшли. Хезмәтләре диагностикага, кесарев кисеменнән соң катлауланууларны кисәтүгә һәм дәвалауга карый. Йөклелек өзелү очрагында яңа туган баланың үзәк нерв системасы перинаталь зарарлануын фаразлаганда баш мие аксымнарының нейроспецифик әһәмиятен өйрәнә. Уйлап табуга 1 авторлык таныклыгы һәм 3 патенты бар.

**ГАВРИ́ЛОВ** Илья Александрович (3.1.1979, Йошкар-Ола ш.), невролог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан мед. ин-тын тәмамлый (2002). 2004–08 елларда Төбәкара клиник диагностика үзәгенең неврология бүлегендә, 2008 дән оештыру-аналитика бүлеге мөдире. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында баш мие кан әйләнеше кискен бозылган авыруларга медицина ярдәме күрсәтү» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ГАЗИ́ЗОВ** Илдар Сабир улы (1.1.1950, Буа р-ны Вольный Стан а.), үсемлекләр физиологы, биол. фән. канд. (1994), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1977), РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында эшли (2005 елга кадәр). 2005–11 дә ТР Фән һәм мәгариф министрлыгында фәнни тикшеренүләрне координацияләү һәм үстерү бүлеге башлыгы. Г. тарафыннан ТРның агросистемага кеше эшчәнлегенең йогынтысы зур булган районнарда агроэкологик куркынычсызлыкны тәэмин итү концепциясе эшләнә. Дәүләт бүләге «Авыл хуҗалыгы культураларының корылыкка чыдамлыгын күтәрү ысулы нигезе буларак, үсемлекләрдә калий әйләнеше һәм тамырларның су үзләштерү процессының ялганыш механизмы» хезмәте өчен бирелә (А.А.Җәләлов б-н берлектә).

**ГАЗИЗУ́ЛЛИН** Камил Мирбат улы (23.4.1958, Казан), машина төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2003), проф. (2006). Россия Космонавтика академиясе академигы (2003). Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң (1981), шунда ук эшли, 1997 елдан сәнәгать экологиясе каф. доценты, 2004 тән профессоры, 2005 тән машина төзелеше технологиясе, металл эшкәртү станоклары һәм инструментлары каф. профессоры; 2007 дән Казан энергетика ун-тының — материаллар белеме, 2009–18 дә динамика һәм машиналарның ныклыгы кафедралары профессоры. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлеше эшкәртүгә авыр бирелүче материалларны үлчәмле эшкәртүнең электрохимик һәм электрофизик ысулларын эшләүгә карый. Уйлап табуга 8 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЙДЕ́НКО** Павел Иванович (15.3.1971, Харьков өлкәсенең Безлюдовка пос.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2011). Киев Суворов уч-щесен (1988), Сумы югары артиллерия командирлары уч-щесен (1992), Казан руханилар семинариясен (2004) тәмамлый. 1992–2005 елларда Рус православие чиркәвенең Мәскәү патриархатында хезмәт итә, 2000 нән Казан руханилар семинариясендә проректор. 2005 тән Казан төзелеш-архит-ра ун-тында. Бер үк вакытта, 2013 тән, Казан технол. ун-тында, гуманитар фәннәр каф. профессоры. Хезмәтләре рус чиркәве һәм монгол яуларына кадәрге Русьта чиркәү-дәүләт мөнәсәбәтләре тарихына карый.

**ГАЙНА́НОВА** Лена Рәшит кызы (23.2.1937, БАССРның Салават р-ны Нәсибаш а.), әдәбият галиме, текстолог, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1998), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан ун-тын тәмамлый (1960). 1960-62 елларда Әгерҗе р-нының «Ленин юлы», 1962-63 тә «Социалистик Татарстан» г-таларында эшли. 1963-2001 дә СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (хәзер ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты) фәнни хезмәткәр, өлкән фәнни хезмәткәр. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н, Г.Ибраһимовның 9 томлыгын (8 нче том), Һ.Такташның 3 томлыгын (2 нче том) төзүчеләрнең берсе. Г.Тукайның Р.Гайнанов төзегән 5 томлык «Әсәрләр»ен текстологик яктан әзерли, «Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы»н төзеп бастыра. Г.Исхакый иҗаты буенча материал җыя, аның әсәрләрен туплый һәм гарәп имлясыннан хәзерге графикага күчереп яза, «Зиндан» җыентыгын төзеп чыгара, 15 томлыгының проектын һәм 1–5 нче томнарын төзи; 1993 елда Чистай р-ны Яуширмә авылында Г.Исхакый музеене нигез сала, әдипнең нәсел шәҗәрәсен төзи. ТР Язучылар берлегенең Г. Исхакый исем. бүләге лауреаты (2008).

**ГАЙНЕТДИ́Н** Дамира Мәгъсүм кызы (17.7.1956, Казан), балет артисты, педагог, ТРның халык артисты (1999). Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тын тәмамлый (2006). 1976–99 елларда ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә, 1988 дән әйдәп баручы солист. «Язгы моң», «Аулак өй», «Сабан туе», «Каз канаты», «Кияү», «Гөлләрем», «Шәрекъ биюе» һ.б. хореографик композицияләрдә ялгыз бию партияләрен башкара. Бер үк вакытта, 1991 дә, репетитор, «Болгар» бию ансамбле солисты (Чаллы ш.). 2001 дән «Казан» бию ансамбле, 2003 тән «Казан» бию ансамбле хореография мәктәбе педагог-репетиторы. 2009 дан Казан ун-тының Филол. һәм сәнгать ин-ты хореография сәнгате каф. доценты. Г. иҗаты проф. осталыгы, образларның сәхнәдә ачык гәүдәләнеше б-н аерылып тора. Медаль б-н бүләкләнә.

**ГАЙНЕТДИ́НОВА** Альбина Фәтхетдин кызы (4.12.1967, Мөслим р-ны Яңа Сәфәр пос.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2012). Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1997), ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли. Хезмәтләре татар теле лексикографиясе һәм морфологиясенә, рус һәм татар телләренең чагыштырма грамматикасына карый.

**ГАЙНЕТДИ́НОВА** Гөлүсә Гомәр кызы (3.6.1952, Әлмәт р-ны Габдрахман а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2007). Казан театр уч-щесен (1976), Казан сәнгать һәм мәдәният ин-тын (1994) тәмамлый. Сәхнә эшчәнлеген 1970 елда Әлмәт татар драма театрында башлый. 1976 да Татар акад. театры труппасына кабул ителә, анда төрле рольләр, ш.и. тирән психологизм б-н сугарылган Гайнавал ролен («Ташкыннар», Т.Гыйззәт) башкара. 1978–87 дә Әлмәт татар драма театрында, 1987–90 да «Радиоприбор» з-дында (Әлмәт ш.) фольклор ансамблендә җитәкчелек итә, 1990 нан Чаллы татар драма театры актрисасы, бер үк вакытта шәһәр театр сәнгате мәктәбендә укыта. Актрисаның иҗат диапазоны киң. Бу аңа драматик, ш.у. комик характердагы рольләрне дә бердәй оста уйнау мөмкинлеге бирә. Г.ның һәр роле тормышчан һәм ышандырырлык. Аеруча зур әһәмияткә ия рольләре — Фатыйма («Сөясеңме — сөймисеңме», Ф.Бүләков), Шәмсия («Кодача», З.Исмәгыйлев), Галимәбану («Галиябану»,

М.Фәйзи), Нәгыймә («Банкрот», Г.Камал), Мәүлия («Без бит авыл малае», Т.Миңнуллин).

**ГАЙНЕТДИ́НОВА** Дания Заһретдин кызы (2.1.1952, Теләче р-ны Олы Тиләҗе а.), язучы, журналист, рәссам, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2008). Казан финанс-икътисад ин-тын (1975), Казан ун-тын (1982) тәмамлый. 1975–84 елларда Татарстан китап нәшрияты мөхәррире, 1984–91 дә ТР Язучылар берлегенең Әдәби фондында эшли. 1991 дән «Татарстан» телерадиокомпаниясенең балалар редакциясендә мөхәррир, радиода алып баручы. Радиоспектакльләр сценарийлары, балалар өчен «Күңел җылысы» (1990), «Өермә» (1992), «Каен җиле» (2007), «Гамьле бизәкләр» (2012) хикәя һәм повесть җыентыклары, сынлы сәнгать буенча мәкаләләр авторы. Пейзаж һәм натюрморт жанрында нәкышь б-н шөгыльләнә, Мәскәүдә, Түбән Новгородта, Төмәндә (барысы да 2005 тә) һ.б. шәһәрләрдә узган һәвәскәр рәссамнар күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәсе Казанда уздырыла (2012).

**ГАЙНЕТДИ́НОВА** Динә Дамир кызы (27.9.1963, Әлки р-ны Кошки а.), невропатолог, мед. фән. д-ры (2007). Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1986), шунда ук нерв авырулары кафедрасында эшли, 2001 дән мед. генетикасы курслы неврология кафедрасында. Хезмәтләре балалар һәм яшьләрдә нерв авыруларын, ш.и. балалар церебраль параличын диагнозлау мәсьәләләренә карый.

**ГАЙНУ́ЛЛИН** Рөстәм Мохтар улы (18.4.1977, Биектау р-ны Биектау тимер юл станциясе пос.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2008). Казан а.х. академиясен тәмамлаганнан соң (1999), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында а.х. экологиясе секторы мөдире булып эшли (2002–05). 2005 елдан ТР МК Аппаратында: Агросәнәгать, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсендә референт, баш киңәшче (2007 дән). Фәнни тикшеренүләре үсемлекләрне саклауның перспектив чараларын, а.х. культураларының яңа төрләрен игү алымнарын һәм а.х. продукциясен эшкәртүне өйрәнү мәсьәләләренә карый.

**ГА́ЙСИН** Ленар Гайнулла улы (24.4.1952, Мөслим р-ны Митрәй а.), химик-технолог, техник фән. канд. (2000), ТРның атказ. химигы (1993), РФнең мактаулы химигы (1995), ТРның атказ. рационализаторы (1998), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), «Енисей» химия комб-тында эшли (Красноярск ш.). 1978–2003 елларда Карпов исем. химия з-дында (Менделеев ш.): цех, җитештерү бүлеге башлыгы, баш инженер, техник директор, ген. директор. 2003–04 тә «Азот» пр-тиесендә (Менделеев) фәнни эшләр буенча директор. 2006 дан ТРның Уйлап табучылар һәм рационализаторлар респ-ка советы (Казан) рәисе урынбасары, 2009 дан рәисе. Хезмәтләре нәорганик матдәләр химиясенә һәм технологиясенә багышлана. Г. натрий сульфидын булдыруның конверсия ысулын, радиокерамика алу, магний сульфаты җитештерү технологиясен эшли. Дәүләт бүләге «Нәорганик матдәләрнең химик технологиясе» циклы өчен лаек була. Хезмәтләре Карпов исем. химия з-дында гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 29 авторлык таныклыгы бар. 1995–2000 дә ТР халык депутаты.

**ГАЙФУ́ЛЛИН** Рөстәм Фәез улы (6.9.1966, Казан), хирург, сәламәтлек саклау өлкәсе оештыручысы, ТРның атказ. табибе (2013), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2010), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан мед. ин-тын (1989), «ТИСБИ» идарә ун-тын (Казан, 2015) тәмамлый. 1990–93 елларда Казан шәһәренең 18 нче клиник хастаханәсе табиб-хирургы. 1993–2006 да Респ-ка клиник хастаханәсендә табиб-хирург, 2006–10 да баш табибнең дәвалау эшләре буенча 1 нче урынбасары, 2010–18 дә баш табиб. 2018 дән 21 нче шәһәр поликлиникасы баш табибе (Казан). Дәүләт бүләге «Бәвел юллары системасында тайпылышлар булган авыруларны дәвалауда яңа технологияләр эшләү һәм кулланышка кертү» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ГАЛИ́** (Галиуллин) Булат Тәлгать улы (1.10.1966, Алабуга ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1991). 1991–96 елларда «Грант» ҖЧҖ директоры, 1996–2001 дә «КамАЗ» АҖ эшләре идарәчесе ярдәмчесе, 2001–09 да ТРның Швейцариядәге вәкиле урынбасары. 2009 дан Казан аграр ун-тының тарих каф. мөдире. Хезмәтләре 19–20 йөзләр чигендә әдәбиятта һәм публицистикада иҗтимагый-сәяси фикер тарихы, Г.Исхакыйның сәяси эшчәнлеге һәм тарихи карашлары мәсьәләләренә карый.

**ГАЛИ́ЕВ** Гарифҗан Гали улы (29.3.1927, Балтач р-ны Арбор а.), төбәкне өйрәнүче, педагог, РСФСР халык мәгарифе отличнигы (1971), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1965). 1949 елдан Балтач р-ны Пыжмара авылы мәктәбендә укытучы. 1960–64 тә «Кама» к-зы рәисе. 1964 тән Балтач р-ны Чепья авылы мәктәбендә: укытучы, директор (1979–87). 1965 тә «Халыклар дуслыгы» мәктәп музеен нигезли һәм аңа җитәкчелек итә (1989 дан ТАССР Дәүләт берләштерелгән музее ф-лы. 2006 дан «Халыклар дуслыгы» туган як тарихы музее» муниципаль бюджет учреждениесе). 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́ЕВ** Илгиз Кадыйр улы (28.5.1937, Апас р-ны Кече Күккүз а.), мед. өлкәсе оештыручысы, мед. фән. д-ры (2002), РФнең атказ. табибе (1999). Кемерово мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), Киров шәһәрендә сан.-эпидемиология станциясе баш табибе булып эшли. 1976 елдан Кемерово өлкә Кызыл Хач җәмгыяте рәисе. 1979 дан Кемерово өлкә башкарма ком-тының сәламәтлек саклау бүлеге мөдире. 1988 дән Кемерово өлкә хастаханәсе баш табибе урынбасары. 1992 дән Кемерово һәлакәтләр медицинасы үзәге директоры. Хезмәтләре шартлаулар, янгыннар, шахталардагы убылулар б-н бәйле һәлакәтләр һәм массакүләм зыян күрүләр очракларында корбаннар санын киметү ысулларын һәм технологияләрен эшләүгә карый. Уйлап табуга 16 патенты бар. Халыкара мед. һәлакәтләре ассоциациясе әгъзасы (1995 тән). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́ЕВ** Камил Әюп улы (23.1.1949, Балык Бистәсе р-ны Яңа Арыш а.), сан. табибе, мед. фән. д-ры (2003). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), сан.-эпид. станциясендә эшли (Әлмәт ш.). 2003 елдан ТР Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Көньяк-көнчыгыш терр. идарәсе башлыгы һәм Әлмәт нефть ин-тының гамәли химия каф. профессоры. Хезмәтләре нефтьнең ТР социумына, фаунасына һәм флорасына тәэсире мәсьәләләренә карый.

**ГАЛИ́ЕВ** Равил Сәид улы (16.6.1947, Казан — 18.7.2006, шунда ук), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук эшли (2006 елга кадәр; бүленеп: 1973–75 тә Ульянов политехник ин-тында). Хезмәтләре газ динамикасы, аэрозольләр механикасына, газ лазерларын һәм пыскучан разрядны модельләштерүгә карый. Лаваль соплоларында һәм опик резонаторларда тибрәнүле-тигезсез газ агымын хисаплау буенча бер төркем мәсьәләләрне чишә. Нәстационар һәм стационар пыскучан разрядның, газ разрядына ия буй һәм аркылы разрядлы лазерларның санлы хисаплау алымнарын үстерә.

**ГАЛИ́ЕВ** Рөстәм Вәлиәхмәт улы (27.8.1960, Октябрь (хәзер Нурлат) р-ны Киекле а.), драма актёры, режиссёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2005), ТРның халык артисты (2011). Казан театр уч-щесен (1987; М.Х.Сәлимҗанов курсы), Мәскәү мәдәният һәм сәнгать ун-тын (2010) тәмамлый. Уч-щедән соң Әлмәт татар драма театрына җибәрелә, анда Сакаев, Зөлкәрнәй («Шундый матур иде розалар», «Тиле яшьлек», И.Абдуллин), Гыйльфан («Тал бөресе имәндә», Т.Миңнуллин), Газизҗан («Йөрәк ничек түзгән?», М.Маликова) рольләрендә уйный. 1990 елда Түбән Кама шәһәренә күчеп килә, «Түбәнкаманефтехим» АҖ каршында яшьләр театр-студиясе оештыра, 2007 дә шуның җирлегендә Түбән Кама татар драма театрын нигезли. 1990–96 да һәм 2002 дән әлеге театрның баш режиссёры, сәнгать җитәкчесе, ш.у. директоры (2009 дан). Эшчәнлегенең башлангыч чорында еш кына комедия жанрындагы пьесаларга мөрәҗәгать итә, спектакльләр куя. Беренче спектакле — Т.Миңнуллинның «Ак тәүбә, кара тәүбә» муз. комедиясе. Аннары бер-бер артлы «Шулай булды шул», «Яшьлек белән очрашу» (Т.Миңнуллин), «Хатыным-алтыным» (Х.Ибраһимов), «Тиле яшьлек» (И.Абдуллин), «Кыз урлау» (М.Кәрим) спектакльләрен сәхнәгә чыгара. Алга таба Г. яшәү мәгънәсе, ил, милләт, кеше язмышы турындагы фәлсәфи фикерләр б-н сугарылган спектакльләр куя: «Җир уллары трагедия-

се» (Һ.Такташ), «Соңгы төн» (И.Юзеев), «Ай тотылган төндә» (М.Кәрим), «Бүре каны» (Н.Гыйматдинова), «Анам кыры» (Ч.Айтматов), «Җилкәнсезләр» (К.Тинчурин), «Нәгыймә» (Р.Зәйдулла), «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин; Әлмәндәр ролен башкара) һ.б. Документаль фильм («Яшәешнең гүзәл мизгелләре») төшерә. Нәфис фильмнарда төшә. ТР Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы. Д.Сираҗиев исем. театраль (2003), М.Сәлимҗанов исем. Респ-ка (2015) бүләкләре лауреаты.

**ГАЛИ́МОВ** Мөхәррәм Нигъмәт улы (18 (31).1.1906, Тугайкүл пос., хәзер Чиләбе өлкәсе, Копейск ш. – 28.4.1990, башка мәгълүмат буенча 1983, Украина, Львов ш.), авиация генерал-майоры, СССРның атказ. хәрби штурманы. 1929 елдан Кызыл Армиядә. Свердловск совет-партия (1929), Ленинград артиллерия (1933), Оренбург очучы-күзәтүчеләр (1935) мәктәпләрен тәмамлый. 1934 елдан СССР Хәрби-Һава Көчләрендә: Испаниядәге гражданнар (1937–38), совет-фин (1939–40), Бөек Ватан (1941–45) сугышларында катнаша. 1941–42 дә Төньяк Кавказ һәм Кырым фронтларында, 1942–45 тә 5 нче Һава армиясендә баш штурман. Сугыштан соң СССР Хәрби-Һава Көчләрендә җитәкче вазифаларда. 1961 дән отставкада. Ленин ордены, биш Кызыл Байрак, Александр Невский, өч 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

**ГАЛИМУ́ЛЛИНА** Гөлшат Хабул кызы (15.9.1953, Лаеш р-ны Хәерби а.), радиоинженер, программист. Казан авиация техникумын (1978), Казан авиация ин-тын (1986) тәмамлый. 1971–94 елларда Казан исәпләү системалары җитештерү берләшмәсендә җыю цехы технологы, махсуслаштырылган конструкторлык бюросы инженер-конструкторы, 1996 дан ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында (хәзер Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-ты) программист, өлкән фәнни хезмәткәр (2014 тән). Г. татар һәм рус телләрендәге 6 томлы «Татар энциклопедиясе» (2002–2019), ш.у. «Казакъстан татарлары» («Татары Казахстана», 2016), «Татарстан Республикасы: массакүләм мәгълүмат чаралары өчен энциклопедик белешмәлек» («Республика Татарстан: энциклопедический справочник для средств массовой информации», 2016), «Габдулла Тукай. Энциклопедия» (2016), «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль символлары» («Государственные и муниципальные символы Республики Татарстан», 2017), «Татарстан Республикасы торак пунктлары» («Населённые пункты Республики Татарстан», 2018) һ.б. басмаларны әзерләү барышында аларның оригинал-макетларын эшләүдә, мәкаләләр һәм иллюстрация материалларын битләргә салуда катнаша. Хезмәтләре Татарстан Респ-касында физика, авыллар тарихын, атаклы татар галимнәрен өйрәнүгә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Зөфәр Шәйдулла улы (1.1.1957, Казан), дин эшлеклесе, Киров өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте (Вятка мөфтияте) рәисе (2013 елдан), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Казан мәдәният ин-тын (1981), «Мир-Араб» мәдрәсәсен (Бохара ш., 1992), Сәддам Хөсәен исем. ун-тны (Багдад, 1997) тәмамлый. Дәүләт бүләге Колшәриф мәчете архит-ра ансамбленең дини концепциясен эшләгәне өчен бирелә (2012). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Нияз Ильяс улы (25.1.1965, Югары Ослан р-ны Кызыл Байрак пос.), невролог, мед. фән. канд. (2002), ТРның атказ. табибе (2005), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). 1988 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1989 дан «Казан» шифаханәсендә эшли. 1991 дән ГИДУВта, 1994 тән Респ-ка мед.-клиника берләшмәсендә. 1995 тән Респ-ка һәлакәтләр медицинасы үзәге директоры. 1998 дән ТР сәламәтлек саклау министрының 1 нче урынбасары. 2005 тән Мед. техникасы һәм Татарстан фармациясе пр-тиесе ген. директоры. 2009 дан Респ-ка СПИДка һәм йогышлы авыруларга каршы көрәш һәм профилактика үзәге баш табибе. Хезмәтләре ТР халкын дарулар б-н тәэмин итүнең формуляр системасын булдыруга, неврология авыруларын ачыклауга, дәвалауга һәм кисәтүгә карый. Дәүләт бүләге даруларны сайлап алу һәм рациональ файдалануның яңа технологиясен булдырганы һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛИУ́ЛЛИНА** Гөлшат Рәис кызы (11.5.1970, Мөслим р-ны Югары Табын а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2010), проф. (2018). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1994), шунда ук эшли, 2008–11 елларда Филол. һәм сәнгать ин-тының хәзерге татар теле каф. мөдире, хәзерге татар теле һәм укыту методикасы каф. профессоры (2012 дән). Хезмәтләре татар теленең лексикологиясенә, семасиологиясенә, ономастикасына, лингвокультурологиягә, социолингвистикага, хәзерге заман гаиләсенең рухи-әхлакый мәсьәләләренә карый. Югары уку йортлары өчен татар теле буенча уку-укыту ярдәмлекләре авторы.

**ГАЛИХА́НОВ** Мансур Флорид улы (24.12.1972, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2009). Казан технол. ун-тын тәмамлаганнан соң (1995), шунда ук эшли, полимерлар һәм композицион материаллар эшкәртү технологиясе каф. профессоры (2009 елдан), Өстәмә һөнәри белем бирү ин-ты директоры урынбасары (2010 нан). Хезмәтләре полимер композицияләр — табигый сыйфаты төрле булган тутыргычлы полимерлар, полимер катнашмалар, күпкатлы һәм «сэндвич» материаллар нигезендә электретлар структурасын һәм үзлекләрен өйрәнүгә карый. Полимер электрет материалларны эшләнмә дәрәҗәсенә җиткереп эшкәртү технологиясен тәкъдим итә; азык-төлек продуктларының әлеге материаллардан эшләнгән төргәкләрдә саклану вакытын озайту буенча югары күрсәткечләргә ирешә. Уйлап табуга патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛЛӘ́МОВА** Әлфия Габделнур кызы (9.11.1955, Брянск өлкәсенең Дятьково ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2011). Казан ун-тын тәмамлый (1978). 1981–96 елларда ТР ФА Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр, 1997 дән ТР ФА Тарих ин-тында, бер үк вакытта, 2000–05 тә, Казан «Әлмәт энциклопедиясе» үзәге җитәкчесе («Әлмәтнефть» НГДУы каршында). Хезмәтләре ТАССРның 1940–80 еллардагы аграр тарихы, социаль-икътисади, сәяси һәм мәдәни үсеше мәсьәләләренә карый; мәктәпләр һәм гомуми белем бирү оешмалары өчен 20 йөз Татарстан тарихы буенча уку әсбаплары автордашы.

**ГАЛЛӘ́МОВА** Динара Хәмит кызы (26.1.1977), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2009), проф. (2015). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1999), шунда ук эшли. Хезмәтләре дөнья икътисадын глобальләштерү, халыкара эшмәкәрлек, халыкара икътисади мөнәсәбәтләр, чагыштырма икътисад һәм сәясәт мәсьәләләренә карый.

**ГАЛЛӘ́МОВА** Юлия Альберт кызы (26.2.1969, Казан), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (2006). Казан мед. ун-тын тәмамлаганнан соң (1992), шунда ук дерматовенерология кафедрасында эшли. 1994–99 елларда Респ-ка тире-венерология диспансерында. 2001 дән Россия дипломнан соң белем бирү мед. академиясенең дерматовенерология кафедрасында. Хезмәтләре балалар һәм яшьләр сәламәтлеген саклауның этик-хокукый нигезләре, дерматовенерология мәсьәләләренә карый.

**ГА́ЛЛЕР** Лев Михайлович (29.11.1883, Россия империясе Бөек Финляндия кенәзлеге, Выборг ш. – 12.7.1950, Казан), совет хәрби-диңгез эшлеклесе, адмирал (1940). Тифлис гимназиясен (1902), Диңгез кадетлар корпусын (1905), Офицерлар артиллерия классын (1912), Хәрби-Диңгез академиясен (1926) тәмамлый. 1905 елдан хәрби-диңгез флотында. Беренче бөтендөнья сугышында линия корабльләре бригадасында флагман артиллерист, «Слава» кораблендә өлкән офицер, 2 нче ранг капитан. Гражданнар сугышы елларында Балтыйк флотында хәрәкәттәге суднолар отряды штабы башлыгы, «Андрей Первозванный» линия корабле командиры. 1921 дән Балтыйк флотында командирлык вазифаларын башкара: Диңгез көчләре штабы башлыгы, 1932–37 дә флот командующие, 2 нче ранг флот флагманы. 1937 дән Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясе Хәрби-Диңгез көчләре башлыгы урынбасары, 1938 дән башлыгы. 1940 тан Хәрби-Диңгез Флоты халык комиссарының корабльләр төзү һәм кораллану буенча урынбасары. Бөек Ватан сугышы чорында яңа корабльләр һәм төзелеш суднолары проектларын эшләү б-н җитәкчелек итә. Репрессияләр корбаны. Үлгәннән соң аклана (1953). Өч Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, ике 1 нче дәрәҗә Ушаков, Россия империясе орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАНИ́ЕВА** Тамилла Фәтхи кызы (4.8.1941, Әзәрбайҗан ССР, Баку), химик-технолог, химия фән. канд. (1971), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Әзәрбайҗан нефть һәм химия ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук эшли. 1997 елдан Казан технол. ун-тының нефть һәм газ эшкәртү химия технологиясе кафедрасында. Хезмәтләре газларны зарарсызландыру өчен катализаторлар, битум продукциясе алу рецептуралары һәм технологияләре, нефть, ягулык һәм май кушылдыклары рецептуралары, табигый битум һәм авыр нефть эшкәртү технологияләрен булдыруга карый. Дәүләт бүләге «Авыр нефть чималы алу һәм эшкәртү процессларында көчле парга әйләнү һәм электромагнит активлашуның инновацион энергия саклаулы технологияләре» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 38 патенты бар. Медаль б-н бүләкләнә.

**ГАРИ́ПОВ** Минсадыйк Гариф улы (16.2.1946, БАССРның Тәтешле р-ны Keче Бәлҗүә а. – 12.10.1998, Ижевск ш.), график, нәкышьче, РФнең атказ. рәссамы (1991), Удмуртия Респ-касының халык рәссамы (1996). Удмурт пед. ин-тын (1970), Мәскәү полиграфия ин-тын (1976) тәмамлый. 1991–98 елларда Удмурт ун-тының нәкышь каф. профессоры. «Удмуртия» китап нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә (1973 тән), «Начар дуслар» («Плохие приятели») удмурт халык әкиятенә, П.Поздеевның «Кечкенә аучы» («Маленький охотник»), А.Клабуковның «Минем әлифбам» («Моя азбука»), Энн-Эвардс Тәкқның «Кыз һәм кабак» («Девочка и тыква») һ.б. китапларына иллюстрацияләр, «Йорт иясе маҗаралары» (1979), «Удмурт халык бәйрәмнәре» (1979–81), «Удмурт ялвару җырлары» (1989), «Терелгән гасырлар» (1998) офортлар сериясе авторы. Урал һәм Идел буе халыклары әкиятләренә иллюстрацияләр ясый. 1980 еллар ахырыннан нәкышь б-н шөгыльләнә: «Яшел белән автопортрет» (1988), «Җиләкле җәй» (1988), «Су кызлары» (1989), «Мунча» (1989), «Ак кош», «Авылда яз» (1992) һ.б. Әсәрләре Третьяков галереясында (Мәскәү), Удмурт сынлы сәнгать музеенда һ.б.да саклана. «Удмурт халкының мифлары, риваятьләре һәм әкиятләре» («Мифы, легенды и сказки удмуртского народа») китабына иллюстрацияләре өчен Удмурт АССРның Дәүләт бүләге бирелә (1988). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980).

**ГАРИ́ПОВ** Эмиль Рамил улы (15.8.1991, Казан), спортчы, Казанның «Ак Барс» хоккей клубы капкачысы. Командада 2007–19 елларда, 2011 дән төп составта. 2008–13 елларда Әлмәт шәһәренең «Нефтяник», 2009–13 тә Яшьләр хоккей лигасының «Барс» клублары өчен чыгыш ясый. 2019 дан «Авангард» хоккей клубында (Омск ш.). Яшүсмерләр арасында дөнья чемпионатының көмеш призёры (2009), Студентларның 24нче (Харбин, Кытай) һәм 25нче (Эрзерум, Төркия) Кышкы Универсиадалары чемпионы (2009, 2011), «Вызов» кубогында катнашучы (2010), U-20 (20 яшькә кадәрге спортчылар) дөнья чемпионаты җиңүчесе (2011), КХЛ Плей-оффының Көнчыгыш конференциясе финалчысы (2013), КХЛның Йолдызлар матчында катнашучы (2018), Гагарин кубогы иясе (2018).

**ГАРИ́ПОВА** Динә Фәһим кызы (25.3.1991, Яшел Үзән ш.), җырчы (меццо-сопрано), ТРның атказ. артисты (2012). Казан ун-тын тәмамлый (2014). Халыкара, бөтенроссия, респ-ка конкурсларында катнаша. «Голос» телевизион шоу җиңүчесе (Мәскәү, 2012; 1 нче урын). Халыкара «Евровидение — 2013» муз. конкурс финалисты. Репертуарын рус, татар һәм чит ил җырлары тәшкил итә («What if?», «Күңел», «Россия», «Ты для меня», «Пятый элемент» һ.б.). 2014 тә беренче «Два шага до любви» соло альбомын чыгара. Россия шәһәрләре буйлап һәм чит илләрдә концерт номерлары б-н гастрольләрдә йөри.

**ГАРИ́ПОВА** Клара Георгиевна (21.6.1946, Казан), вет. табибе, биол. фән. канд. (1979), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнан соң (1969), шунда ук эшли, хирургия каф. доценты (1995). Дәүләт бүләге терлекләрне махсус тематика буенча дәвалау алымы булдырганы өчен бирелә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**ГАРИФУ́ЛЛИН** Ришат Госман улы (2.12.1966, Тәтеш р-ны Кече Әтрәч а.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013). Казан пед. ин-тын (1990), Казан технол. ун-тын (2002) тәмамлый. 1990–93 елларда респ-кадагы төрле пр-тиеләрдә эшли. 1993 тән «Татнефть» АҖдә, «Елховнефть» НГДУы нефть чыгару идарәсендә цех башлыгы (2000 нән), баш технолог (2001 дән), АҖнең нефть һәм газ әзерләү бүлегендә әйдәп баручы инженер (2002 дән), «Татарстан нефть-газ эшкәртү» идарәсенең баш инженер урынбасары (2005 тән), баш инженер – идарә башлыгының беренче урынбасары (2012 дән). Уйлап табуга 10 патенты бар. Дәүләт бүләге Идел буе-Урал чыганаклары шартларында нефть әзерләүнең сыйфатын күтәрү технологияләрен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ГАРИФУ́ЛЛИНА** Аида Эмиль кызы (30.9.1987, Казан), опера җырчысы (сопрано), ТРның һәм РФнең атказ. артисты (2013, 2020). Нюрнберг Югары музыка мәктәбен (2007, З.Ерузалем классы), Вена музыка һәм башкару сәнгате ун-тын (2011, К.Виска классы) тәмамлый. Вена дәүләт опера театры солисты (2013 тән). Төп партияләре: Мюзетта («Богема», Дж.Пуччини), Джильда, Нанетта («Риголетто», «Фальстаф», Дж.Верди), Норина, Адина («Дон Паскуале», «Мәхәббәт шәрабы», Г.Доницетти), Памина, Деспина, Сюзанна, Церлина («Тылсымлы флейта», «Фигароның өйләнүе», «Дон Жуан», В.Моцарт), принцесса Евдоксия («Яһүд кызы», Ф.Галеви), Наташа Ростова («Сугыш һәм тынычлык», С.Прокофьев), Шәмаха патшабикәсе, Кар кызы («Алтын әтәч», «Кар кызы», Н.Римский-Корсаков). Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург һ.б. шәһәрләрдә соло концертлар бирә. Халыкара, бөтенроссия, респ-ка конкурсларында, аерым шәхесләргә багышланган хәйрия концертларында катнаша. Медаль б-н бүләкләнә.

**ГАСА́НОВ** Ализадә Солтан оглы (13.5.1963, Әзәрбайҗан ССРның Лачин р-ны Ленинканд а.), фармаколог, токсиколог, биол. фән. д-ры (2007). Әзәрбайҗан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1989), Казан вет. медицинасы академиясенең фармакол. һәм токсикология кафедрасында эшли, доцент (2012). Төп хезмәтләре фармакол., токсикология өлкәсенә карый.

**ГАТАУ́ЛЛИН** Әнәс Газиз улы (5.1.1948, Тымытык р-ны Тымытык а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2011), проф. (2012), ТРның атказ. юристы (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1976–79 елларда Азнакай р-ны халык мәхкәмәсе халык судьясы. 1979–87 дә ТАССР Югары мәхкәмәсе әгъзасы. 1987–90 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1990–91 дә ТР Конституцион күзәтчелек ком-ты рәисе урынбасары, 1991–2000 дә рәисе. 2000–10 да ТР Конституция мәхкәмәсе рәисе урынбасары. 2010 нан Казан ун-тының конституцион хокук һәм административ хокук кафедрасында. Хезмәтләре конституцион хокук, РФ субъектларында конституция мәхкәмәсе күзәтчелеге мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАТАУ́ЛЛИНА** Ирина Алексеевна (23.2.1958, Югары Ослан р-ны Куралово а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2009), проф. (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1982), Казан төзүче инженерлар ин-тында (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты): институт комсомол ком-тының идеология буенча секретаре (1982–87); 1990–2010 елларда тарих һәм культурология кафедрасында укыта, доцент (2001 дән). 2010 нан Казан техник ун-тында: җәмәгатьчелек б-н элемтәләр каф. профессоры (2010–14), каф. мөдире (2015–18); 2019 дан социол., политология һәм менеджмент каф. профессоры. Хезмәтләре Урта Идел буе халыкларының нэп елларындагы социаль-икътисади мөнәсәбәтләрен һәм шул төбәк авылларының тормыш-көнкүрешен өйрәнүгә карый.

**ГАФА́РОВ** Шамил Хәмит улы (11.5.1969, Апас р-ны Апас а.), хакимият эшлеклесе, икътисад фән. канд. (2001). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1992). 1992–97 елларда ТР Финанс министрлыгының инспектор-ревизоры, сектор башлыгы. 1997–98 дә ТР финанс министры ярдәмчесе. 1998–2005 тә ТР Премьер-министры ярдәмчесе. 2005 тән ТР МК Аппараты җитәкчесе. Бер үк вакытта, 2010 нан, ТР Премьер-министры урынбасары. Язмалары Татарстанда сәнәгать үсеше мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАФИЯ́ТОВ** Илгиз Зиниятулла улы (9.2.1954, Аксубай р-ны Яңа Дума а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2008), проф. (2010), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2009). Казан химия-технол. ин-тын (1984), Мәскәү гуманитар-икътисад ин-тын (1998) тәмам-

лый. 1979–2002 елларда «Түбәнкаманефтехим» АҖдә эшли. 2003 тә Казан технол. ун-тының Түбән Кама ф-лы директоры, бер үк вакытта, 2004–09 да, иҗтимагый һәм гуманитар фәннәр каф. мөдире, 2009 дан Казан технол. ун-ты Түбән Кама мәгълүмати технологияләр һәм телекоммуникацияләр ин-тының икътисад һәм менджмент каф. мөдире. Хезмәтләре моносәнәгать шәһәренең социаль-икътисади үсеше, ш. у. шәһәрдә мәдәни, милли конфессияләр арасындагы мөнәсәбәтләр стратегиясен эшләү һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 3 патенты бар.

**ГАФФА́РОВА** Фәридә Юлдаш кызы (9.12.1951, Свердловск өлкәсенең Березовский ш. — 17.10.2006, Казан; Кукмара р-ны Камышлы авылында җирләнә), тарихчы, тарих фән. канд. (1997). Казан ун-тын тәмамлый (1974). 1975–96 елларда ТР ФАнең Тел, әдәбият, тарих ин-тында лаборант, фәнни хезмәткәр; 1997–2006 да Тарих ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре Садри һәм Әхмәдһади Максудиларның, чит илләрдә яшәгән күренекле татар эшлекләренең сәяси-иҗтимагый эшчәнлегенә, татар иҗтимагый фикере тарихы мәсьәләләренә карый.

**ГӘРӘ́ЕВ** Тимур Мәхмүт улы (15.11.1961, Белоруссия ССР, Гродно ш.), генерал-майор (2005), сәясәт фән. канд. (2001). РСФСР Югары Советы исем. Мәскәү югары гомумгаскәри командирлар уч-щесен (1982), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1991), РФ Кораллы Көчләре Генераль штабы Хәрби академиясен (1999), РФ Оборона министрлыгы Хәрби ун-тын (2014) тәмамлый. 1982–2000 елларда СССР һәм РФ Оборона министрлыгы Үзәк аппаратында җитәкче вазифаларда. 2000 нән Коры җир гаскәрләренең Коралларны кыскарту турындагы килешүләрне тормышка ашыру үзәге башлыгы. 2004–09 да РФ Коры җир гаскәрләре баш штабында. 2009–12 дә Мәскәү шәһәре Төбәк куркынычсызлык департаментында. 2013 тән Хәрби фәннәр академиясенең Төбәкара иҗтимагый оешмасы башкарма директоры. Почёт ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГӘРӘ́ЕВА** Илнара Илгиз кызы (1.8.1983, Мөслим р-ны Мөслим а.), филолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). Казан ун-тын тәмамлый (2006). 2002 елдан «Гасырлар авазы – Эхо веков» ж-лы редакциясендә, баш мөхәррир урынбасары (2010 нан). Дәүләт бүләге «Гасырлар авазы – Эхо веков» ж-лын нәшер итүдә катнашканы өчен бирелә. Язмалары тел белеменә, татар әдәбиятына карый.

**ГЕРА́СИМОВ** Валерий Васильевич (8.9.1955, Казан), совет һәм Россия хәрби эшлеклесе, армия генералы (2013), РФнең атказ. хәрби белгече (2009), РФ Герое (2016). Казан Суворов хәрби уч-щесен (1973), Казан югары танк командирлар уч-щесен (1977), Р.Я.Малиновский исем. Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (1987), РФ Кораллы көчләре Ген. штабы Хәрби академиясен (1997) тәмамлый. 1977–84 елларда Ерак Көнчыгыш хәрби округында (батальон штабы башлыгы). 1987 дән Балтыйк буе, Мәскәү, Төньяк Кавказ, Ерак Көнчыгыш хәрби округларында җитәкче вазифаларда. 2007–09 да Ленинград, 2009 дан Мәскәү, 2012 дә Үзәк хәрби округлар гаскәрләре командующие. 2012 дән РФ Кораллы Көчләре Ген. штабы башлыгы. 2009–12 дә Кызыл мәйданда Җиңү бәйрәме парады б-н җитәкчелек итә. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», «Хәрби казанышлар өчен», 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт өчен» орденнары, медальләр, чит дәүләтләрнең орденнары һәм медальләре б-н бүләкләнә.

**ГЕРА́СИМОВ** Константин Игоревич (16.1.1973, Казан), физик, физика-матем. фән. канд. (2003), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1995), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында. Хезмәтләре диэлектрик кристалларның җир кабыгында сирәк очраучы ионнарының оптик, лазер, ЭПР һәм магнитооптик спектроскопиясенә карый. Дәүләт бүләге гидрогеологиядә һәм Татарстан нефть чыганакларын үзләштерүгә күзәтчелек итүдә аппаратлы-методик индикаторлар комплексын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ГЕРА́СИМОВ** Михаил Егорович (19.6.1935, Зәй р-ны Югары Баграҗ а.), геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (1994), Украинаның мактаулы җир асты байлыкларын тикшерүчесе (1998), Казан ун-тын тәмамлый (1958). «Татнефтегеофизика» (Бөгелмә ш., 1958–64), «Днепрогеофизика» (Симферополь ш., 1964–68) трестларында, Краков геофизика пр-тиесендә (Польша, 1968–72), «Кырымгеология» ҖБдә (Симферополь ш., 1972–97) эшли. 1997 елдан «Кырымгеофизика» геол. пр-тиесендә баш геофизик. Көнчыгыш-Европа платформасының тирәнтен төзелешен һәм эволюциясен, Кырым ГЭСы р-ны геологиясен һәм геодинамикасын, Кара диңгез буе регионы геодинамикасын һәм нефть-газ бирүчәнлеген тасвирлый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЛА́ЗОВ** Юрий Владимирович (30.3.1962, Курск ш.), хокук белгече, РФнең атказ. юристы (2011). Саратов юридик ин-тын тәмамлый (1987). 1990–2000 елларда Курск шәһәренең Ленин районы мәхкәмәсендә судья, 2000–03 тә мәхкәмә рәисе урынбасары. 2003–06 да Курск өлкә мәхкәмәсе судьясы. 2006–08 дә Белгород өлкәсе Арбитраж мәхкәмәсе рәисенең 1 нче урынбасары, 2008–12 дә мәхкәмәсе рәисе. 2013 тән Идел буе округы Федераль арбитраж мәхкәмәсе рәисе. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЛУ́ХОВА** Лариса Юрьевна (30.8.1976, Кукмара р-ны Кукмара пос.), хакимият эшлеклесе, ТРның атказ. юристы (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1998). 1996–2001 елларда Казан шәһәренең кулланучылар хокукын яклау ком-ты юристы. 2001–05 тә ТР Финанс министрлыгы юристы, бүлек башлыгы урынбасары. 2005–10 да ТР МК Аппаратының Хокук идарәсендә сектор мөдире, 2010–12 дә Хокук идарәсе башлыгы урынбасары. 2012–13 тә «Татавтодор» ААҖдә бүлек башлыгы. 2013–17 дә ТР юстиция министры. 2017 дән ТР Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы.

**ГЛУШАКО́В** Александр Иванович (19.7.1967, Казан), мед. статистигы, мед. фән. д-ры (2006). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1992), табиб-статист булып эшли, 1993 елдан «Татмединформ» ФҖБдә мед.-стат. мәгълүмат җыю һәм эшкәртү төркеме җитәкчесе. 1995 тән Респ-ка «Медсоцэконом» үзәгенең мед. статистикасы бүлеге башлыгы. 2004 тән Казан мед. ун-тының мед. экспертизасы бүлеге мөдире. Хезмәтләре демография (фәнни таныпбелү методологиясе, балалар үлеме сәбәпләрен өйрәнү) өлкәсенә карый.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Айрат Марат улы (4.8.1965, Казан), археолог, тарихчы, тарих фән. д-ры (2017). Казан ун-тын тәмамлый (1990). 1993–94 елларда Болгар дәүләт тарих-архит-ра музей-саклаулыгының археол.-реставрация бүлеге мөдире. 1994 тән ТР ФАнең Тел, әдәбият, тарих ин-тында, Тарих ин-тының Археол. тикшеренүләр үзәгендә, 2014 тән Археол. ин-тының урта гасырлар археологиясе бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре. Идел-Кама каскады сусаклагычлары зонасында, Кама арьягы, Идел алды терр-яләрендә, Казан Кремленең төньяк-көнбатыш һәм төньяк өлешләрендә, Болгар шәһәрлегендә археол. тикшеренүләр б-н җитәкчелек итә. «Вопросы истории фортификации» альманахы (Мәскәү) редколлегиясе әгъзасы. Хезмәтләре Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урданың Болгар олысы, Казан ханлыгы тарихы һәм археологиясе мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИНА** Асия Наил кызы (7.2.1958, Норлат (хәзер Яшел Үзән) р-ны Кече Шырдан а.) төзүче инженер, җәмәгать эшлеклесе, ТРның атказ. төзүчесе (2007). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1980). 1980–2002 елларда Главтатстройның 2 нче төзелеш трестында инженер, проектлау буенча баш белгеч. 2002 дән «Акведук» ҖЧҖ проектлау оешмасында проект баш инженеры, техник директор, 2006 дан директор. Г. җитәкчелегендә торак йортлар («Замандаш», «Симфония» микрор-ннары һ.б.), мед. максатындагы биналар («Ава-Казан» мед. үзәге, Казан ун-тының мед. кластеры объектлары), кунакханәләр, уку корпуслары, адм. биналар, дини корылмалар, сәүдә комплекслары һ.б. проектлана. Иҗтимагый-хәйрия эшчәнлеге алып бара. 2015 тән «Кече Шырдан — тарихи торулык, бөек мәгърифәтче Каюм Насыйриның кече ватаны яңарышы» фонды» коммерциячел булмаган оешмасын төзүдә башлап йөрүче һәм аның башкаручы директоры.

**ГО́ГОЛЕВ** Владимир Борисович (27.8.1949, Алексеев р-нының Алексеев а.), паразитолог, вет. фән. д-ры (2002), Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнан соң (1972), Балык Бистәсе

р-ны вет. станциясендә эшли. 1975–96 елларда Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тының (хәзер Хайваннарның токсикологик, радиацион һәм биол. куркынычсызлыгы федераль үзәге) арахно-энтомология һәм экотоксикология бүлекләрендә кече фәнни хезмәткәр, фәнни хезмәткәр һәм өлкән фәнни хезмәткәр. 1996 дан Казан вет. медицинасы академиясендә өлкән укытучы, доцент, бер үк вакытта, 2009 дан, Казан эшмәкәрлек һәм хокук ин-ты профессоры. Фәнни тикшеренүләре паразитология һәм экология мәсьәләләренә карый. «Идел-Вятка регионында кан белән тукланучы бөҗәкләр фаунасы һәм аларга каршы көрәш» («Фауна кровососущих насекомых в Волго-Вятском регионе и борьба с ними») монографиясе автордашы. РФ Ветеринария департаменты күрсәтмәсе б-н төрле елларда гадәттән тыш хәлләр очракларында вет. куркынычсызлыгы б-н бәйле мәсьәләләрне хәл итү максатыннан Саратов өлкәсе, Казакъстан, Әрмәнстанга җибәрелә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы, 3 патенты бар.

**ГОЛОВИ́Н** Андрей Вячеславович (30.4.1951, Мәскәү), архитектор, ТРның атказ. архитекторы (2004). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), «ТатНИПИнефть»тә (Бөгелмә), 1981 елдан «Татинвестгражданпроект»та, 2009 дан «Казан» җитештерү-төзелеш берләшмәсе» ҖЧҖдә архитектор булып эшли. Г. проектлары буенча Әлмәт шәһәрендә «Татойлгаз»ның адм. бинасы (1991), Казан Кремлендә Колшәриф мәчете ансамбле (1997–2005, проектның автордашы, баш архитекторы, 2012 дә Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек була), Әлмәт шәһәрендәге «1в» һәм «2в» микрорайоннары (2006–07), Казандагы Спортның су төрләре сарае (2010, проект автордашы) төзелә. Архитекторлар берлеге әгъзасы (1984). Медаль б-н бүләкләнә.

**ГО́ЛУБЕВА** Руфина Константиновна (7.11.1954, Киров өлкәсенең Санчурск р-ны, Сметанино а.), акушер-гинеколог, сәламәтлек саклау өлкәсе оештыручысы, ТРның атказ. табибе, РФнең атказ. сәламәтлек саклау хезмәткәре (2011), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1978). 1979–80 елларда Түбән Кама шәһәре мед. учреждениеләрендә акушер-гинеколог булып эшли. 1980–81 дә Казан шәһәре 4 нче бала тудыру йортында, 1981–90 да Горький тимер юлының Казан бүлекчәсе хастаханәсендә, 1991 дә 19 нчы шәһәр хастаханәсенең Гаиләне планлаштыру үзәгендә акушер-гинеколог. 1991–92 дә 19 нчы шәһәр хастаханәсенең Гаиләне планлаштыру үзәге мөдире, 1992–95 тә дәвалау эшләре буенча баш табиб урынбасары, 1995 тә Казан шәһәре хакимиятенең сәламәтлек саклау идарәсе баш акушер-гинекологы. 1995–99 да 19 нчы шәһәр хастаханәсе баш табибе. 1999–2005 тә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсендә бала сәламәтлеге һәм бала тудыруда ярдәм мәсьәләләре буенча башлык урынбасары. 2005–11 дә ТР сәламәтлек саклау министры урынбасары. 2011 дән Казан шәһәре сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшли. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында баш мие кан әйләнеше кискен бозылган авыруларга медицина ярдәме күрсәтү» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ГОМӘ́РОВ** Марат Мотаһар улы (18.9.1939, Казакъстан ССРның Талды-Курган ш.), биолог, биол. фән. д-ры (1983), проф. (1985). Мәскәү ун-тының биол.-туфрак һәм химия ф-тларын тәмамлаганнан соң (1968), шунда ук эшли, туфрак биологиясе каф. профессоры (1985 елдан), 1977–2007 дә туфрак белеме ф-тының халыкара багланышлар деканы, 1997–2013 тә Халыкара укыту-фәнни биотехнол. үзәгенең туфрак биотехнологиясе бүлеге мөдире. Г. — азотның туфрактагы, үсемлекләрнең ризосферасы һәм филлосферасындагы, хайваннарның ашказаны-эчәк трактындагы микробиол. трансформациясен өйрәнү өлкәсендә танылган белгеч; прокариотларның (бактерияләр һәм археяләр) күпчелеге азотфиксациягә сәләтле булу турындагы күзаллауларны нигезләп һәм үстереп, бу сәләтнең аерым бактерияләрнең тар төркеменә генә хас булуы турындагы карашларга җитди үзгәрешләр кертә. Кузаклы булмаган үсемлекләрнең, ш.у. хайваннарның азотфиксация үзенчәлекләрен өйрәнү нигезендә ассоциатив азотфиксациянең (ассоциатив симбиоз) биосферага «биологик азот» күчүдә иң мөһим процесс булуы турындагы тәгълиматны ныгыта. Бер үк төр бактерияләре күзәнәкләрендә ике капма-каршы процессның — азотфиксация һәм денитрификация — процессларының берьюлы бару ихтималын әйтә (бу фараз соңрак эксперимент юлы белән исбатлана). Хезмәтләре үсемлекләр һәм хайваннар азотфиксациясе һәм денитрификациясенә карый. М.В.Ломоносов исем. бүләк һәм Мәскәү хөкүмәте бүләкләре лауреаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГОМӘ́РОВ** Нәфис Фәрит улы (25.1.1958, Азнакай штп), геолог-нефтьче, техник фән. канд. (1999), ТРның атказ. геологы (2012), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Мәскәү ун-тын (1980), РФ Хөкүмәте каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (2004) тәмамлый. 1980 елдан «Татнефть» АҖдә эшли, «Әлмәтнефть» НГДУында баш геолог – идарә башлыгы урынбасары (2003 дән). Хезмәтләре ятмаларның нефть бирүчәнлеген арттыру технологияләрен эшләү һәм аз продуктлы коллекторларны үзләштерүгә карый. Дәүләт бүләге гидрогеологиядә һәм Татарстан нефть чыганакларын үзләштерүгә күзәтчелек итүдә индикаторларның аппаратлы-методик комплексын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ГРЕ́ВЦЕВ** Валерий Афанасьевич (21.9.1941, Ростов өлкәсенең Аксай ш.), аналитик-радиоспектроскопист, физика-матем. фән. д-ры (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), шунда ук эшли. 1979 елдан ЦНИИгеолнерудта, оптика һәм радиоспектроскопия лаб-ясе мөдире (2005 тән). Хезмәтләре табигый һәм синтезланган объектларны өйрәнгәндә спектроскопик ысуллар куллануга карый. Руда булмаган файдалы казылмалар (баритлар, каолиннар, фосфатлар һ.б.) составына керүче минералларның фазалар составын һәм структур-кристалл-химик үзлекләрен ачыклый. Файдалы казылмаларның минераль составын һәм технол. үзлекләрен өйрәнү өчен электрон микроскопия б-н беррәттән электрон парамагнит резонансы (ЭПР), магнит-төш резонансы (ЯМР) ысулларын куллануның фәнни-методик нигезләрен эшли. Уйлап табуга 2 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГРИЦИ́ШИН** Сергей Николаевич (28.1.1966, Әлмәт ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Мәскәү нефть һәм газ ин-тын тәмамлаганнан соң (1988), «Сахалингаз» газ чыгару идарәсендә эшли. 1993 елдан «Татнефть» АҖдә: мастер, инженер-технолог, «Әлмәтнефть» НГДУында цех башлыгы урынбасары, Инженерлык үзәгендә торбаүткәргечләрне һәм нефть чыгару җиһазларын коррозиядән саклау (2000 нән), фәнни-техник (2005 тән) бүлекләре, АҖнең техник бүлеге (2008 дән) башлыгы. Уйлап табуга 3 патенты бар. Дәүләт бүләге нефть кудыруның ышанычлылыгын арттыру технологияләрен эшләү һәм сәнәгатьтә гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ГРИ́ШИН** Сергей Николаевич (19.5.1975, Казан), физиолог, биофизик, биол. фән. д-ры (2012). Казан техник ун-тын тәмамлаганнан соң (1998), Казан мед. ун-тының нормаль физиол. кафедрасында эшли, 2006 елдан Казан ун-тының кеше һәм хайваннар физиологиясе кафедрасында. 2010 нан Казан техник ун-тының Радиоэлектроника һәм телекоммуникацияләр ин-тында, 2012 дән телевидение һәм мультимедиа системасы (хәзер радиофотоника һәм микродулкынлы технологияләр) каф. профессоры, тере системаларда мәгълүмат тапшыру механизмнары лаб-ясе мөдире, «Видеомәгълүматларның психофизиологик аспектлары» фәнни-мәгариф үзәге директоры. Хезмәтләре нерв-мускул тапшырулары модуляцияләрен һәм синаптик сыгылмалылыкны өйрәнүгә карый. Нигезендә кире бәйләнеш принцибы буенча эндоген пуриналар б-н төп медиаторны — ацетилхолинны аеру яткан мускул көчләренең аккумуляцияләре механизмын тасвирлый. Уйлап табуга 9 патенты бар.

**ГРЯЗНО́В** Алексей Николаевич (28.3.1954 БАССРның Караидел р-ны Усть-Байки а.), психолог, психол. фән. д-ры (2009). СССР Дәүләт куркынычсызлыгы ком-тының Ф.Э.Дзержинский исем. Югары чик сакчылары командирлары уч-щесен (Алма-Ата, 1978), Югары партия мәктәбен (Харьков ш., 1990), Казан техник ун-тын (2002), Казан мед. ун-тын (2006) тәмамлый. 1972–98 елларда СССР һәм РФ Дәүләт куркынычсызлыгы ком-тында хезмәт итә (Хабаровск ш.). 1998 дән Казан мед. ун-тында: кадрлар бү-

леге башлыгы (2007 гә кадәр), бер үк вакытта мед. һәм гомуми психол. кафедрасында. 2008 дән РМАнең Пед. һәм психол. ин-тында: шәхес психологиясе лаб-ясе мөдире, 2011 дән баш фәнни хезмәткәр. Бер үк вакытта, 2008 дән, «ТИСБИ» идарә академиясендә махсус психол. каф., 2011 дән Удмурт ун-ты (Ижевск ш.) социаль психол. һәм конфликтология каф. профессоры. Хезмәтләре алкоголизм һәм наркомания б-н авыручыларны терциар социальләштерү, девиацияләр социаль психологиясе мәсьәләләренә карый.

**ГУ́БСКАЯ** Валентина Петровна (3.10.1943, Украина ССР, Донецк өлкәсенең Моспино ш.) химик, химия фән. канд. (1984), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1966), РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли. Хезмәтләре кинетикага һәм электрохимик процесслар барышында металларның эрү механизмын өйрәнүгә, оптик актив спирт һәм аминнар синтезы ысулларын эшләүгә, фуллереннар химиясенә карый. Дәүләт бүләге «Фуллереннарның органик чыгарылмалары — электроника һәм биомедицина өчен наноматериаллар булдыруда төзелеш блоклары» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ГУСЬКО́ВА** Ирина Алексеевна (15.8.1965, Әлмәт ш.), нефть-газ чыганакларын эшкәртү технологы, техник фән. д-ры (2010). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1987). 1987–89 елларда Мәскәү нефть һәм газ ин-тының Татарстан кичке ф-тында нефть чыганакларын эшкәртү һәм файдалану кафедрасында эшли (Әлмәт ш.), 1990–92 дә «Уренгойгаздобыча» газ промыселы идарәсендә нефть һәм газ чыгару операторы (Яңа Уренгой ш.), 1992–93 тә Әлмәт р-ны нефтьүткәргечләр идарәсендә нефтьнең химик анализы лаборанты, 1993–99 да Әлмәт нефть ин-тының нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү һәм файдалану кафедрасында лаборант, ассистент, өлкән укытучы, 1999–2005 тә «Татнефть» ААҖ Инженерлык үзәгенең фәнни-техник бүлеге башлыгы, директорның фән буенча урынбасары (Әлмәт ш.). 2005 тән Әлмәт нефть ин-тында: нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү һәм файдалану каф. доценты (2005 тән), профессоры, мөдире (2008 дән), профессоры (2018 дән). Россия табигыять фәннәре мөхбир-әгъзасы. Хезмәтләре нефтьнең авыр чыгарылышлы запаслары чыганакларын эшкәртүнең нәтиҗәлелеген күтәрү, нефтьнең техноген үзгәрешле ятмаларын файдаланганда катлауланулар булдырмау технологияләрен тикшерү һәм эшләү, нефть чыгару технологияләренең үзара тәэсирен тикшерү нигезендә аларны камилләштерү мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 11 патенты, файдалы модельгә 3 патенты, электрон хисаплау машиналары өчен программалар теркәлү хакында 7 рәсми таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

**ГУ́ЩИН** Эдуард Владимирович (3.3.1939, Әзәрбайҗан ССР, Кировабад ш.), кинорежиссёр, сценарийлар язучы, РФнең мактаулы кинематографисты (2004), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2009). Казан хәрби авиация-техника уч-щесен (1959), Казан ун-тын (1969) тәмамлый. 1965–81 елларда Казан телевидение студиясендә фильмнар төшерү буенча өлкән, баш мөхәррир. 1991 дән ТР Кинематография үсеше дәүләт фонды (1993 тән ТР Кинематография дәүләт ком-ты) рәисенең беренче урынбасары, 2001 дән Казан кинохроника студиясенең җаваплы мөхәррире. «Кама өстендәге кыл» («Струна над Камой»), «Өзлексез тасма» («Непрерывная лента»), «Казан Кремле» («Казанский Кремль») фильмнарының сценарийлары авторы һәм режиссёры. ТАССР Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. бүләге лауреаты (1974). «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Хәмбәл Габдрахман улы (4.11.1926, Мари автономияле өлкәсенең Мари-Төрек р-ны Татар Кетнәсе а.), хәрби табиб, кардиолог, мед. фән. канд. (1971), мед. хезмәте полковнигы (1975). 1961 елда Хәрби мед. академиясен (Ленинград) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша: 1944–45 тә 1 нче Балтыйк буе, 4 нче Украина фронтларында марштагы команда фельдшеры. 1945–78 дә Совет армиясендә хезмәт итә: 1961 дән Төрекмәнстан хәрби округы полкында хәрби табиб, өлкән табиб, мед. хезмәте башлыгы, 1967 дән Урта Азия хәрби округы госпитале ординатор-терапевты. 1978–97 дә Алма-Ата мед. ин-тында госпиталь терапиясе кафедрасында. 1998–2008 дә Казан шәһәре 18 нче клиник хастаханәсе поликлиникасының табиб-кардиологы. Хезмәтләре эчке авыруларны (гипертония, миокард инфарктларын дәвалау) өйрәнүгә карый.

**ГЫЙЛӘ́ҖЕВ** Илгиз Идрис улы (14.4.1957, Казан), хокук белгече, ТРның атказ. юристы (2003). П.Лумумба исем. Халыклар дуслыгы ун-тын тәмамлый (Мәскәү, 1984). 1984–87 елларда ТАССР Социаль тәэминат министрлыгында өлкән инспектор. 1987–89 дә Казанның Бауман р-ны халык мәхкәмәсе халык судьясы. 1989–96 да ТР Югары мәхкәмәсе әгъзасы, 1996–2011 дә рәисе урынбасары, 2011 дән рәисе. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЫЙЛӘҖЕТДИ́НОВА** Гөлинә Хәйретдин кызы (13.12.1958, Мәскәү өлкәсенең Щёлково ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2012), проф. (2016). Казан ун-тын (хәзер Казан федераль ун-ты) тәмамлаганнан соң (1981), шунда ук эшли, 1999–2000 дә филол. ф-ты деканы урынбасары. Харбиндагы Хэйлунцзян ун-тында (1991–95, Кытай), Гиссен шәһәрендәге Юстус Либиг исем. ун-тның Славистика ин-тында (ГФР, 2001–03) чакырулы профессор. Хезмәтләре рус-татар, рус-фарсы тел бәйләнешләренә, татар теле грамматикасына, тәрҗемә белеменә, рус әдәби теле тарихына, тарихи лексикология һәм сүз ясалышы, лексикография, лингвокультурология, чит тел буларак рус телен укыту методикасына карый.

**ГЫЙЛӘҖЕТДИ́НОВА** Ирина Владимировна (29.10.1946, Ставрополь краеның Георгиевск ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2010), проф. (2010), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), В.И.Ленин исем. Респ-ка фәнни китапханәсендә китапханәче булып эшли. 1970–76 елларда комсомол эшендә. 1976–79 да Казан ун-тының политэкономия кафедрасында. 1980 нән Казан технол. ун-тының икътисад (2002 гә кадәр), менеджмент һәм эшмәкәрлек кафедраларында. Хезмәтләре хуҗалык системаларының инновацион үсеше өлкәсенә карый. Фәнни тикшеренүләренең нәтиҗәсе инновацион үсеш стратегиясен эшләгәндә, сәнәгый куркынычлар б-н идарә итү, җитештерү хуҗалык объектларының идарә нигезендә ышанычлы эшләвен үстерү системаларын формалаштыру һәм камилләштерү өлкәсендә кулланыла. Дәүләт бүләге ТРның нефть химиясе комплексында җитештерү потенциалын модернизацияләү процессында сәнәгый куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм пр-тиеләрнең яшәүчәнлеген күтәрү механизмын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ГЫЙЛЕМХА́НОВА** Эльвира Фәрит кызы (10.4.1966, Яшел Үзән ш.), драма актрисасы, режиссёр. ТРның халык артисты (2015). Казан театр уч-щесен (1987), Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тын (2004) тәмамлый. 1985 елдан Татар «Әкият» курчак театрында. Образга кереп уйнау остасы, зурлар һәм балалар өчен тормышчан, кызыклы рольләр башкара. Төп рольләре: Кабато («Ханума», А.Цагарели), Алисә төлке («Буратино», А.Толстой буенча), Ана («Апушның тылсымлы төшләре», Р.Бохараев), Ана («Өч кыз», А.Хәиров), Фатыйма («Али-баба һәм кырык юлбасар», В.Смехов), Мадам Штальбаум («Щелкунчик», Э.Т.А.Гофман), Анакай, Алмагач, Убырлы карчык («Казлар-аккошлар», Л.Кожевников) һ.б. Режиссёр-куючы буларак, «Мөгезле Кәҗә килә» («Идёт Коза рогатая», М.Протасова), «Принцесса Карпинка» (А.Шмидт) спектакльләрен куя. Россия шәһәрләрендә һәм чит илләрдә узган халыкара фестивальләрдә катнаша: Оренбург, Рязань (Россия), Канны (Франция), Стара-Загора (Болгария), Ботроп, Брауншвейг (Германия), Брест (Беларусь), Меджидия (Румыния), Бурса (Төркия) һ.б. ТР Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1992).

**ГЫЙЛЬМА́НОВ** Хәмит Хәмис улы (13.8.1949, Чаллы ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2010), ТРның һәм РФнең атказ. химигы (2004, 2008). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), «Түбәнкаманефтехим» АҖдә эшли (Чаллы ш.), этилен з-ды директоры (1998–2003), 2003 елдан директор урынбасары, баш инженер, бер үк вакытта, 2005 тән, Казан технол. ун-тының химия сәнәгате машиналары һәм аппаратлары кафедрасында, проф. (2011 дән). Хезмәтләре химия һәм нефтехимия технологияләре өлкәсенә карый. Этилен җитештерү куәтен арттыру һәм технол. җиһазларын яңарту программасын гамәлгә ашыруда; пи-

ролиз мичләрен һәм колонналы җиһазларны реконструкцияләүдә; сыек фазалы изопрен синтезының энергия саклаулы технологиясен, чыныктыру-парга әйләндерү аппаратларын төзәтү технологиясен әйләнешкә кертүдә катнаша. ТР Дәүләт бүләге (2002), РФ Хөкүмәте бүләге (2011) лауреаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЫЙЛЬМЕТДИ́НОВ** Илдар Ирек улы (3.9.1962, Кама Тамагы р-ны Келәнче а.), дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. Казан пед. ин-тын (1983), ВЛКСМ ҮК каршындагы Югары комсомол мәктәбен (1989, Мәскәү), Төньяк-Көнбатыш дәүләт хезмәте академиясен (С.-Петербург, 2007) тәмамлый. 1986 елдан ВЛКСМның Кама Тамагы район ком-ты 2 нче секретаре, Актаныш район ком-ты 1 нче секретаре булып эшли. 1990 нан ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты секретаре, бер үк вакытта, 1992 дән, ТР Яшьләр оешмалары советы идарәсе рәисе. 1994 тән ТР Балалар һәм яшьләр эшләре буенча дәүләт ком-ты рәисе урынбасары. 2001 дән ТР Яшьләр һәм спорт эшләре буенча министрның 1 нче урынбасары. 2003 тән РФ Дәүләт Думасы депутаты, бер үк вакытта, 2003–11 дә, Думаның Физик культура һәм спорт ком-ты рәисе урынбасары, 2011–16 да Мәгариф ком-ты әгъзасы, 2016 дан Милләтләр эшләре ком-ты рәисе һәм Хисап комиссиясе рәисе. 2007 дән Татарларның федераль милли-мәдәни автономиясе советы рәисе. ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (2009). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЫЙНИЯ́ТОВ** Хәлил Зиннур улы (20.9.1956, Чиләбе өлкәсенең Магнитогорск ш.), химик, техник фән. канд. (2002), ТРның атказ. химигы (1998), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). Казан ун-тын (1979), Казан финанс-икътисад ин-тын (2006) тәмамлый. 1979 елдан (бүленеп) Казан дары з-дында: мастер, өлкән инженер, участок, цех башлыгы, лак-буяу җитештерү пр-тиесе директоры (1997), ген. директор (2003–17). 1998–2000 дә ТРның Дәүләт мөлкәте б-н идарә итү ком-тында бүлек башлыгы; 2000–03 тә «Казан оптика-механика заводы» АҖдә: ген. директор урынбасары, директор (2002 дән). 2012–19 да ТР Дәүләт Советы депутаты. Уйлап табуга патенты бар. Дәүләт бүләге көндәшлеккә сәләтле продукция эшләүнең диверсификацион технологияләрен булдыруда катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЫЙНИЯТУ́ЛЛИН** Равил Фәрит улы (20.12.1955, Чита ш.), дәүләт эшлеклесе. 1980 елда Чита пед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1982 дән ВЛКСМның Чита шәһәр ком-ты 1 нче секретаре, 1985 тән КПССның шәһәр ком-ты инструкторы, 1987 дән шәһәр башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1990 нан КПССның шәһәр ком-ты 1 нче секретаре, 1991 дән шәһәр башкарма ком-ты рәисе, Чита шәһәре хакимияте башлыгы. 1996 дан Чита өлкәсе хакимияте башлыгы, 2008–13 тә Байкал аръягы крае губернаторы. 2000–06 да «Байкал аръягы энциклопедиясе» («Энциклопедия Забайкалья») баш мөхәррире.

**ГЫЙНИЯТУ́ЛЛИН** Рим Абдулла улы (18.9.1943, Үзбәкстан ССР, Сәмәрканд өлкәсенең Заамин р-ны Обручево станциясе), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. канд. (1988), Каракалпакстанның һәм Үзбәкстанның атказ. ирригаторы. Ташкент төзелеш техникумын (1962), Ташкент Патентлау ин-тын (1973), Ташкент А.х.н ирригацияләштерү һәм механикалаштыру ин-тын (1977) тәмамлый. 1965–85 елларда Үзбәкстан ССР Мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгы Баш идарәсендә инженер, өлкән инженер, идарә башлыгы урынбасары, идарә башлыгы, Баш идарә башлыгы урынбасары, Баш идарә башлыгы, Үзбәкстан ССР мелиорация һәм су хуҗалыгы министры урынбасары. 1986–97 дә Үзбәкстан ССР Госагропромы, Госпланы рәисенең 1 нче урынбасары – Үзбәкстан ССР министры, Үзбәкстан ССР (Үзбәкстан Респ-касы) мелиорация һәм су хуҗалыгы министры, Үзбәкстан Респ-касы Премьер-министры урынбасары, Үзбәкстан Респ-касы Госкомпрогнозстаты (берләштерелгән Госплан һәм Госстат) рәисе. 1997–2000 дә Халыкара Аралны коткару фонды башкарма ком-ты беренче рәисе – Үзбәкстан Респ-касы министры. 2000–06 да Арал диңгезе бассейны проектлары б-н идарә буенча GEF агентлыгы җитәкчесе – Үзбәкстан Респ-касы министры. «Почёт билгесе», Хезмәт Кызыл Байрагы (СССР), Дуслык, Хезмәт даны (Үзбәкстан Респ-касы) орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЫЙНИЯТУ́ЛЛИН** Шакир Нигъмәтулла улы (15.3.1895, Самара губ., Бөгелмә өязе Кәрҗәле а. — 3.4.1946, Мәскәү), генерал-майор (1941). В.И.Ленин исем. Хәрби инструкторлар мәктәбен (1919), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1931), Генштаб академиясен (1939) тәмамлый. 1918 елдан Кызыл Армиядә. 1919–24 тә эскадрон командиры, Төркестан 2 нче аерым укчы дивизиянең кавалерия полкы командиры. 1926–28 дә 8 нче Аерым Төркестан кавалерия бригадасының 80 нче кавалерия полкы командиры, 84 нче кавалерия полкы штаб башлыгы. 1930 еллар уртасыннан Кызыл Армия Разведка идарәсендә, Монголиядә хәрби киңәшче, 1937–38 дә Разведка идарәсенең 9 нчы бүлеге монгол-шөнҗан бүлекчәсе башлыгы. 1939 дан Кызыл Армия начсоставы кавалерия курсларының уку-өйрәтү бүлеге башлыгы (Мәскәү), 1940 тан комбриг, генерал-майор. Бөек Ватан сугышында — Ген. штабның Оператив бүлегендә. Оператив хәлне бәяләү максатында күптапкырлар фронтка җибәрелә. Ленин ордены, өч Кызыл Йолдыз, Кызыл Байрак орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Туган авылында Г. музее ачыла.

**ДАВЫ́ДОВ** Денис Владимирович (28.2.1974, Әстерхан ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2013). Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1996). 1996–97 елларда Минзәлә р-ны Матвеевка урта мәктәбендә тарих, 1997–98 дә Түбән Кама р-ны Кармалы урта мәктәбенә инглиз теле укытучысы. 2005 тән Казан технол. ун-тының тарих һәм җәмәгатьчелек б-н багланышлар кафедрасында. Хезмәтләре ТАССР крәстияннәренең 1920 еллардагы мәдәнияте мәсьәләләренә карый.

**ДА́ИШЕВА** Альбина Кен кызы (26.7.1961, Казан), архитектор, реставратор, дизайнер. Казан архит-ра-төзелеш ун-тын тәмамлаганнан соң (1992), «Искусство» иҗат-җитештерү пр-тиесендә декоратив-гамәли сәнгать рәссамы. 1996 елдан Казан шәһәре хакимияте башлыгы каршындагы Архит-ра һәм шәһәр төзелеше баш идарәсе белгече. 2001 дән ТР Сәнгать фондында менеджер һәм проектлаучы. 2004–05 тә «ЗАБИР» ҖЧҖ директоры. 2005 тән Казан архит-ра-төзелеш ун-тының интерьер кафедрасында. Бер үк вакытта, 2009 дан, «Казан Кремле» музей-тыюлыгында белгеч. «Казан Кремле ансамблен саклау, реставрацияләү һәм файдалану концепциясе»н булдыруда, Тупчылар утары, Губернатор сарае, Александров пассажы, Кекин йорты комплексларын төзекләндерү проектларын эшләүдә, Әстерхан шәһәрендә «Ак мәчет» (2008) һәм Самара шәһәре мәчете (2009) интерьерларын проектлауда, Колшәриф мәчете интерьерларының декоратив элементларын (ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 2012) эшләүдә катнаша.

**ДАНИ́ЛОВА** Надежда Ивановна (5.3.1958. Казан), вет. фармакологы, токсиколог, биол. фән. д-ры (2010). Казан вет. ин-тын тәмамалый (1980). 1980–82 елларда Алтай крае Бийск р-ны «Лесное» җәнлек үрчетү с-зында ферма мөдире булып эшли; 1981–82 дә Лаеш р-ны «Атабай» кошчылык с-зында азыкларны бәяләү лаб-ясе мөдире, 1982–85 тә Респ-ка нәселле терлек үрчетү берләшмәсенең «Элита» баш нәсел пр-тиесе (Биектау авылы) зоотехникы. 1985–95 тә Бөтенсоюз (Бөтенроссия) вет. фәнни-тикшеренү ин-тында, токсикология бүлеге фәнни хезмәткәре (1991–95). 1995 тән Казан вет. медицинасы академиясендә, зоогигиена каф. доценты (2011). Хезмәтләре терлекләрне тукландыруда ферментлы препаратлар куллану мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 2 патенты, авторлык таныклыгы бар.

**ДАУ́ТОВ** Рафаил Җәмил улы (17.11.1955, Кыргызстан ССР, Җәләлабад өлкәсенең Базар-Курган р-ны Кызыл-Унгур пос.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1999). Казан. ун-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук эшли, хисаплау математикасы каф. профессоры (2000 елдан), бер үк вакытта, 1992 дән, математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре матем. физиканың сызыкча һәм нәсызыкча мәсьәләләрен чишүнең санлы ысулларына, матем. модельләштерү һәм хисаплау математикасына карый. 2 нче һәм 4 нче тәртип квазисызыкча эллиптик тигезләмәләр өчен чикле элементлар ысулының суперҗыелучанлык теориясен тәкъдим итә, өлкә эчендә каршылыклы эллиптик вариацион тигезсезлекләрне чишү ысулларын, чикләнмәгән өлкәләрдә эллиптик операторлар өчен спектраль мәсьәләләр классын чишү ысулларын эшли һәм нигезли. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2012).

**ДАУ́ТОВА** Резидә Вәгыйзь кызы (19. 1. 1961, Казан), тарихчы, журналист, тарих фән. д-ры (2012). Казан ун-тын тәмамлый (1984). 1978 елдан «Яшь ленинчы» г-тасы редакциясендә, 1981–89 да «Ленинец» г-тасы хәбәрчесе. 1993 тән «Вечерняя Казань» г-тасында, мәдәният, фән һәм мәгариф бүлеге мөхәррире (1999 дан). 2000 нән «Восточный экспресс» г-тасында. 2002 дән «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясендә радиотапшыруларның төбәкара һәм милләтара программалар бүлеге мөдире. 2003–04 тә «Татар дөньясы» – «Татарский мир» г-тасында. 2004–13 тә ТР ФАдә җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары б-н багланышлар бүлеге җитәкчесе. Бер үк вакытта Казан ун-тында электрон массакүләм мәгълүмат чаралары теориясе һәм практикасы кафедрасында укыта. Хезмәтләре төбәк һәм милли, Татарстан, Идел буе һәм Урал алды массакүләм мәгълүмат чаралары үсеше тарихына карый. «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» конкурсының «Ел журналисты» номинациясе лауреаты (1997). Медаль б-н бүләкләнә.

**ДӘҮЛӘТБА́ЕВА** Диана Наил кызы (7.1.1983, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2013), проф. (2018). Казан пед. ун-тын тәмамлаганнан соң (2004, хәзер Казан федераль ун-ты), шунда ук эшли, 2016–17 елларда герман филологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре рус, инглиз, төрек телләренең чагыштырма фразеологиясенә, икетелле лексикография, төрле төзелешле телләрнең чагыштырма типологиясе мәсьәләләренә карый. Чит телләр укытучылары ассоциациясе (RegELTA) әгъзасы. Социогуманитар фәннәр өлкәсендә «ТРның иң яхшы яшь галиме» (2013).

**ДӘҮЛӘТШӘ́** (1821, Самара губ. Бөгелмә өязе, хәзер Азнакай р-ны Кәкре Елга а. — 1908, шунда ук), дин эшлеклесе, кабер ташларына уеп язучы. Д. тарафыннан ясалган кабер ташы татарларның Бикбау авылыннан (Минзәлә р-ны) чыккан Туеш нәселенең 7 буыны вәкилләре истәлегенә куелган. Шәҗәрәдән алынган мемориаль язу гарәп «тәгълик» ысулы б-н уелган. Орнаметлы бизәлеше юк.

**ДӘҮЛӘ́ТШИНА** Айгөл Ядкәр кызы, туфрак гыйлеме белгече, а.х. фән. канд. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2014). РАХФАнең Татарстан Агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-тының агроэкология һәм микробиол. лаб-ясендә фәнни хезмәткәр. Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касы терр-ясендә экологик чиста а.х. продукциясе җитештерү өчен нефть б-н пычранган җирләрне наноструктур сорбент һәм абориген микроорганизмнар-деструкторлар консорциумын кулланып рекультивацияләүнең инновацион технологияләрен эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ДӘҮЛӘ́ТШИНА** Мингаләм Зәйни кызы (22.5.1922, хәзер Оренбург өлкәсенең Матвеевка р-ны Яңа Әмир а. — 5.9.1992, Оренбург өлкәсенең Грачёво р-ны Таллы а.), сыер савучы, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1937–77 елларда Грачёво р-ны Коминтерн исем. с-зының сөтчелек фермасында эшли. Районда һәм өлкәдә һәр сыердан елга уртача сөт саву буенча иң югары күрсәткечләргә ирешә (1959 да 4913 *кг*, 1960 та 5580 *кг*, 1969 да 6543 *кг*). Герой исеме терлекчелекне күтәрүдә һәм сөт савып алуда зур уңышларга ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, ике Октябрь Революциясе ордены; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын, дүрт көмеш медальләре б-н бүләкләнә. Д.ның портреты Грачёво халык музеенда саклана.

**ДЕЛОНЕ́** Борис Николаевич (3.3.1890, С.-Петербург — 17.7.1980, Мәскәү), математик, СССР ФА мөхбир әгъзасы (1929). Киев ун-тын тәмамлый (1913), 1916 дан Киев политехник ин-тында, 1922–35 тә Ленинград ун-ты профессоры; 1935 тән Мәскәү ун-тында, бер үк вакытта, 1932 дән, СССР ФАнең Матем. ин-тында (Мәскәү), алгебра бүлеге мөдире (1942 дән). Хезмәтләре алгебра, хисаплау геометриясе, матем. кристаллографиягә карый. Гаусcның үзара бәйлелек законын исбатлый; матем. алымнарның берсе аның исеме б-н — Делоне триангуляциясе дип атала. «Аналитик геометрия» курсын эшли. Бөек Ватан сугышы елларында Казан ун-тында югары матем. буенча лекцияләр укый. Альпинизм буенча СССРның спорт остасы (1935). Таулы Алтайның Катун сыртындагы пик Д. исемен йөртә. Н.И.Лобачевский исем. Халыкара бүләк лауреаты (1977). Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ДЁМИН** Тимур Викторович (8.4.1973, Казан), невролог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016), ТРның атказ. табибе (2018). Казан мед. ун-тын тәмамлый (1996). Төбәкара клиник диагностика үзәгенең баш мие кан әйләнеше кискен бозылган авырулар бүлеге мөдире. Бөтенроссия конкурсы җиңүчесе (2008, 2013). Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлеше ангионеврологиягә карый. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында баш мие кан әйләнеше кискен бозылган авыруларга медицина ярдәме күрсәтү» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ДЕМУХАМЕ́ТОВ** Николай Александрович (27.8.1920, хәзер Кемерово өлкәсенең Мариинск ш. — 9.10.1981, Красноярск краеның Ужур р-ны Кызыл Күл а.), колхозчы, Соц. Хезмәт Герое (1948). 1934–70 елларда К.Маркс исем. к-зда, 1970–81 дә Ужур р-ның «Ленинский путь» с-зында эшли (звено җитәкчесе, вет. фельдшеры, тимерче, көтүче). Герой исеме Д. җитәкләгән звено тарафыннан 12 *га* мәйданда һәр *га* дан 33,5 *ц* бодай уңышы җыеп алган өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 3 нче дәрәҗә Дан ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ДЕНИ́СОВ** Константин Петрович (24.2.1938, Казан), моторлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1988), РФнең атказ. фән. эшлеклесе (1999). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Космик ракеталар сәнәгатенең фәнни-сынау үзәгендә эшли (Мәскәү өлкәсе), объект башлыгы (1974 елдан), фәнни эшләр буенча директор урынбасары (1989 дан), фәнни тикшеренүләр үзәге җитәкчесе (2011 дән). Хезмәтләре сыеклыклы ракеталарның мотор җайланмаларын җир өстендә стендлы сынауларга, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карый. Д. җитәкчелегендә «Союз» (Р-7) ракеталарына стендлы сынаулар уздырыла. Медаль б-н бүләкләнә.

**ДИБЕРДИ́ЕВ** Тимур Рөстәм улы (24.12.1980, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2012). Казан технол. ун-тын тәмамлаганнан соң (2003), шунда ук эшли, полимерлар һәм композицион материалларны эшкәртү технологиясе каф. профессоры (2012 елдан). Хезмәтләре полимер һәм композит материаллар җитештерү һәм эшкәртү процессларына карый. Д. катнашында эпоксид олигомерларга нигезләнгән тыгыз челтәрле полимер матрицалар җитештергәндә релаксацион процесслар барышының үзенчәлекләре ачыклана; тирәлек шартларына бәйле рәвештә полимерларның физик-механик һәм электромагнитик үзгәрешләрен фаразлау ысуллары эшләнә. Уйлап табуга 14 патенты бар.

**ДИМӨХӘММӘ́ТОВ** Рифкать Салих улы (12.8.1946, Пермь ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2006), проф. (2008). Кустанай пед. ин-тын тәмамлый (1975, Казакъстан ССР). 1970 елдан комсомолның Кустанай өлкә ком-тында инструктор, студент, укучы яшьләр һәм пионерлар бүлеге мөдире, 1977 дән Кустанай балалар йорты директоры урынбасары, 1978 дән директоры. 1981–2002 дә Кустанай өлкә укытучылар белемен күтәрү ин-тының тәрбия эшләре кабинеты мөдире, мәгариф идарәсе каф. мөдире. 2002 дән Чиләбе пед. ун-тының теоретик һәм гамәли психол. каф. доценты, психол.-пед. фәннәре каф. мөдире, социаль хезмәт, пед. һәм психол. каф. профессоры. Мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү һәм кабаттан әзерләү академиясе каршында Андрагогика мәсьәләләре буенча иҗтимагый совет әгъзасы (2004, Мәскәү). «Квалификация күтәрү системасында фасилитация» фәнни мәктәбен нигезләүче. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ДИНМӨХӘММӘ́ТОВ** Габделхәй Ишмөхәммәт улы (1891, Вятка губернасы, Түнтәр а. – 1922, шунда ук), педагог, җәмәгать эшлеклесе. Идел буенда татар мәктәпләре булдыру һәм «Якты юл» ж-лын нәшер итүдә башлап йөрүчеләрнең берсе.

**ДИНМӨХӘММӘ́ТОВ** Рамил Шәфыйк улы (8.2.1960, Әлмәт р-ны Елховой а.), геолог, ТРның атказ. геологы (2012), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1983), «Татнефть» АҖдә эшли, Нефть һәм газ чыганаклары геологиясе идарәсе башлыгы (2005 елдан). Дәүләт бүләге «Татнефть» АҖ ресурс базасын үстерү өчен каралган алымнар һәм технологияләр комплексын сәнәгатькә кертү һәм аның фәнни нигезләре» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ДОГРУ́Л** (Ибраһимова) Фәүзия Габдерәшит кызы (1887–1985, Истанбул ш.), нашир, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Дин һәм җәмәгать эшлеклесе Габдерәшит Ибраһи-

мовның кызы. Гомеренең күпчелек өлешен Төркиядә эмиграциядә уздыра. Төркия тарихында беренче буларак хатын-кызлар өчен «Асар-е нисван» («Âsâr-ı Nisvan») журналын чыгара башлый (1925; 1926 елдан «Хатыннар дөньясы» («Kadınlar Dünyası») исеме б-н чыга, барлыгы 28 саны дөнья күрә), оештыру эшләреннән тыш, журнал өчен мәкаләләр яза, анда ш.у. сеңлесе Кадриянең дә мәкаләләре басыла. «Милли гаилә мәҗмугасы» («Milli Aile Mecmuasi») журналын нигезләүдә катнаша. Д. берничә китап, ш.и. 1909 һәм 1915 елларда Россиядә нәшер ителгән (2017 дә Казанда кабат бастырыла) «Аш остасы» китабы авторы. Ире, төрек дипломаты Нефиз Догрул Мисырда эшләгәндә Каһирәдә балалар өчен үзе камил белгән инглиз һәм француз телләрендә Мөхәммәд пәйгамбәр турында китап язып бастыра. Каһирәдә илаһият галиме Муса Бигиевны тәрбия итүдә һәм соңгы юлга озатуда катнаша (1949), аның архивын һәм китапханәсен Финляндиягә озата.

**ДО́МРАЧЕВА** Наталья Евгеньевна (14.8.1951, Мурманск өлкәсенең Полярный ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1974 елдан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында. Хезмәтләре ЭПР спектроскопиясенә, металл мезогеннар, дендримерлар, нанокисәкчәләр, молекуляр динамика, магнит электр эффектлары, спин-үзгәрүчән системаларга карый.

**ДУБРО́ВСКИЙ** Александр Владимирович (3.8.1946, Чуаш АССРның Ядрин ш.), табиб отоларинголог, сәламәтлек саклау өлкәсе оештыручысы, ТАССРның атказ. табибе (1988), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Респ-ка клиник хастаханәсендә эшли. 1976–2005 елларда Тәтеш үзәк район хастаханәсендә: 1984 елга кадәр баш табиб урынбасары, 1995 тән баш табиб. 1984–94 тә ТАССР халык депутатларының Тәтеш район советы рәисе урынбасары. 2005 тән Тәтеш р-ны сәламәтлек саклау бүлеге башлыгы, 2006 дан ТРның Тәтеш муниципаль р-ны башлыгы урынбасары. Фәнни хезмәтләре гаилә медицинасы, авыл җирлегендә сәламәтлек саклауны үзгәртеп кору, мед. күзәтчелеге өлкәсендә кисәтү чараларын оештыру, авыл халкына беренчел мед.-сан. ярдәме күрсәтү мәсьәләләренә карый. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында онкология хезмәте белән идарә һәм яңа оештыру технологияләрен гамәлгә кертү...» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ЕГО́РОВ** Александр Васильевич (24.9.1957, Украина ССР, Кировоград ш.), физик, физика-матем. фән. канд. (1990), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1979), шунда ук квант электроникасы һәм радиоспектроскопия кафедрасында эшли. Хезмәтләре ван-флекча парамагнетиклар, югары температуралы үтәүткәргечләрне ТМР һәм төш квадруполь резонанс алымнары б-н тикшерүгә карый. Дәүләт бүләге ван-флекча парамагнетиклар физикасына багышланган хезмәтләр циклын эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ЕГО́РОВ** Иван Михайлович (21.1.1961, Мамадыш р-ны Җөри а.), хуҗалык-хакимият эшлеклесе, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013), ТРның атказ. азык-төлек сәнәгате хезмәткәре (2007). 1980–81 елларда Әфганстан Респ-касындагы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Казан пед. ин-тын (1987), РФ Хөкүмәте каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (1994) тәмамлый. 1987 дән «Сәүдә үзәге» рестораны директоры урынбасары, 1990 нан «Яшьләр үзәге» рестораны директоры, 1995 тән Казанның Совет р-ны җәмәгать туклануы идарәсе башлыгы, 1996 дан «Татспиртпром» ҖБ Усад спирт заводының ген. директоры. 2002 дән «Ак Барс» холдинг компаниясе» АҖ директоры. Дәүләт бүләге диагностика, профилактика, микотоксикозларны дәвалау чараларын булдыруда һәм аграр комплекска кертүдә катнашканы өчен бирелә. 4 нче һәм 5 нче чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутаты (2009–19). Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЕЖКО́В** Владимир Олегович (14.2.1966, Чистай р-ны «Кызыл Октябрь» с-зы), ветеринар, вет. фән. д-ры (2008), проф. (2010). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнннан соң (1990), Чистай р-ны «Луч» җәнлек үрчетү с-зында баш вет. табибе булып эшли. 1995–99 елларда Татарстан төбәк вет. лаб-ясендә вет. табибе-эпизоотолог, 1999–2007 дә шунда ук бактереология бүлеге мөдире. 2007 дән «Татарстан агрохимия һәм туфрак белеме» фәнни-тикшеренү ин-тында өлкән, баш фәнни хезмәткәр, терлекчелек һәм игенчелектә био-, нанотехнологияләр бүлеге мөдире, бер үк вакытта, 2010–11 дә, Казан технол. ун-тының азык-төлек җитештерү технологиясе, 2011 дән Кече пр-тиеләрнең азык-төлек инженериясе кафедралары мөдире. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре био- һәм нанотехнологияләргә, а. х. терлекләре морфологиясе һәм патологиясенә, сканирлаучы зондлы микроскопиягә, нанокисәкчекләрнең тәэсир итү механизмнарын һәм аларның хайваннар организмында адреслы тапшырылу юлларын өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 30 патенты бар. Бөтенроссия вет. медицинасы патологоанатомнары ассоциациясе әгъзасы (2006 дан).

**ЕЖКО́ВА** Асия Мәҗетдин кызы (1.2.1966, Бөгелмә ш.), биолог, биол. фән. д-ры (2007), проф. (2011), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2014). Казан вет. ин-тын (1988), Казан технол. ун-тын (2012) тәмамлый. 1988–1990 елларада ТАССР А.х. министрлыгының Бөгелмә р-нындагы «Пугачёв» с-зында баш вет. табибе, 1990–2001 дә «Раифа» вакытлы хезмәт коллективында 2 нче категорияле белгеч, РСФСР «Зверопром» фәнни-җитештерү берләшмәсенең «Луч» җәнлек үрчетү с-зы әйдәп баручы белгече, бер үк вакытта, 1990–91 дә, Мех өчен җәнлек һәм кролик үрчетү фәнни-тикшеренү ин-ты фәнни хезмәткәре (Мәскәү өлкәсенең Раменки пос.). 2001 дән Татарстан агрохимия һәм туфракны өйрәнү фәнни-тикшерү ин-ты (2017 дән РФА КГҮнең Татарстан агрохимия һәм туфракны өйрәнү фәнни-тикшеренү ин-ты) өлкән, әйдәп баручы һәм баш фәнни хезмәткәре, бер үк вакытта, 2011 дән, Казан технол. ун-ты профессоры. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләрен «туфрак–үсемлек–хайван–продукция» системасын, вет. экологиясен өйрәнү, продуктларга вет.-сан. экспертизасы уздыру мәсьәләләре, а.х.нда био-, нанотехнологияләр: наноматериаллар нигезендә препаратлар эшләп чыгару, терлекләрнең продуктлылыгын арттыру һәм продукциянең сыйфатын күтәрү өчен аларның зыянсызлыгын һәм организмга тәэсир итү механизмын өйрәнү тәшкил итә. Уйлап табуга 31 патенты бар. Дәүләт бүләге «Экологик яктан зыянсыз авыл хуҗалыгы продукциясе алу максатыннан нефть белән пычранган җирләрне наноструктур сорбент һәм абориген микроорганизм-деструкторлар кулланып рекультивацияләүнең инновацион технологияләрен эшләү һәм Татарстан Республикасы территориясендә кулланылышка кертү» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ЕКИМЕ́НКО** Валентина Александровна (16.10.1951, Кукмара ш.), геофизик, ТРның атказ. геологы (2001), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Казан ун-тын тәмамлый (1974), «ТНГ-групп» ҖЧҖдә эшли, баш геолог — ген. директор урынбасары (2006 елдан). РФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (2011). Дәүләт бүләге «Татнефть» АҖ ресурс базасын үстерү өчен каралган алымнар һәм технологияләр комплексын сәнәгатькә кертү һәм аның фәнни нигезләре» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ЕМЕКЕ́ЕВ** Александр Александрович (3.11.1952, Чистай р-ны Чуаш Ялтаны а.), социлог, социол. фән. д-ры (2005), проф. (2005). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2008). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук эшли: инженер, кече, өлкән фәнни хезмәткәр, гомуми химия технологиясе каф. доценты. 1999 елдан Әлмәт нефть ин-ты ректоры. Хезмәтләре сәнәгый җитештерүдә һөнәри эшчәнлек мотивациясе, хезмәт социологиясе мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

**ЕМЕЛЬЯ́НОВ** Сергей Валентинович (3.1.1970), концертмейстер, педагог, ТРның халык артисты (2013). Казан консерваториясен (скрипка классы) тәмамлый (1994). Студент елларында ук (1992 елдан) «LaPrimavera» оркестрына кабул ителә, өч елдан аның концертмейстеры була. Бер үк вакытта, 1992–97 дә, концерт эшчәнлеге б-н бергә консерватория каршындагы Махсус музыка мәктәбендә укыта (скрипка б-н квартет). 1999 да Орфордта (Канада) һәм Монреаль ун-тында (Э.Туровская классы, скрипка) халыкара мастер-классларда стажировка уза. 2008 дән ТР Дәүләт симф. оркестрында: оркестр концермейстеры һәм солисты (2011), бер үк ва-

кытта, 2015 тән үзе оештырган «Nobilis» борынгы һәм классик музыка ансамбле солисты һәм аның җитәкчесе. Ансамбль ш.у., татар халык һәм Татарстан композиторлары көйләрен файдаланып, халыкара проектлар әзерли. 2017 дән Балалар сәнгать мәктәбендә укыта. Е. Россиядә (Екатеринбург, Иркутск, Төмән, Оренбург, Пермь һ.б.) узган һәм халыкара (Швеция, Франция, Швейцария, Украина, Төркия, Кытай, Көньяк Корея) муз. фестивальләрдә катнаша. Халыкара һәм респ-ка яшь башкаручылар конкурслары һәм фестивальләренең жюри рәисе һәм әгъзасы.

**ЕПИ́ХИН** Александр Юрьевич (16.10.1961, Рязань өлкәсенең Шилово р-ны Ибредь а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2005), проф. (2006). Мәскәү юридик ин-тын тәмамлый (1991). 1984–94 елларда Воркута шәһәре эчке эшләр органнарында. 1994–97 дә Воркута шәһәр мәхкәмәсендә федераль судья. Бер үк вакытта, 1995–96 да, Воркута идарә, бизнес һәм хокук ин-тында укыта. 1997–2006 да Сыктывкар ун-тында, 1999–2000 дә юридик ф-т деканы урынбасары, 2000 нән деканы. 2006–12 дә Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында (Казан), 2010 га кадәр юридик ф-т деканы. 2012 дән Казан ун-тының җинаять процессы һәм криминалистика кафедрасында. Хезмәтләре җинаять процессуаль хокукына, җинаять-мәхкәмә эшләрендә шәхеснең куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЕРОФЕ́ЕВА** Ирина Валерьевна (11.7.1968, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2011). проф. (2015). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1990), шунда ук эшли. Хезмәтләре рус әдәби теле тарихына, тарихи сүз ясалышы, лексикология, концептология, когнитив лингвистикага карый. Русистика мәсьәләләрен яктырткан уку-укыту–методик ярдәмлекләр авторы.

**Е́СИН** Радий Германович (1.8.1961, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (2006), проф. (2012), ТРның атказ. табибе (2015). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), шунда ук нерв авырулары кафедрасында эшли. 1990–92 елларда һәм 2000 нән Казан мед. академиясендә неврология кафедрасында, 2006 дан вертеброневрология һәм мануаль терапия кафедрасында. 1992–99 да ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка клиник-диагностика үзәгендә неврология бүлеге мөдире. Хезмәтләре ашыгыч неврология ярдәме, ш.и. инсультларга диагноз кую һәм дәвалауга, нейроиммунологиягә һ.б.га карый. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш белгеч-неврологы. Бөтенроссия неврологлар җәмгыятенең идарә әгъзасы.

**ЖА́РИН** Денис Евгеньевич (11.7.1972, Пенза ш.), материаллар белеме өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2006). Пенза техник ун-тын тәмамлый (1994), Пенза технол. ин-тында эшли (1997–99). 1999 елдан Кама инженерлык-икътисад академиясендә (Чаллы ш.), машиналар һәм кою производствосы технологияләре каф. профессоры (2009 дан). Хезмәтләре композит төзү материалларын өйрәнүгә карый. Термореактив полимер композицион материалларны эксплуатацияләү үзлекләрен тикшерә, вибрация йотучан полимер төзү композитларын барлыкка китерүнең фәнни нигезләрен эшли.

**ЖЕЛТУ́ХИН** Виктор Семёнович (28.2.1956, Биектау р-ны Семиозёрка а.), математик, физика-матем. фән. д-ры (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук эшли, матем. стат. каф. мөдире (2009 елдан). Хезмәтләре түбән темп-ралы плазманы матем. модельләштерүгә карый. Түбән басымлы югары ешлыклы йомык үзеннән-үзе килештерелгән матем. модель һәм аның органик һәм нәорганик материаллар б-н тәэсирләшүенең матем. модельләрен эшли. Спектраль параметрның коэффициентларга һәм тигезләмәнең әһәмияте функциясенә нәсызыкча керүе шарты б-н үз күрсәткечләр мәсьәләсен гадәти булмаган чишүнең булуы шартларын ачыклый.

**ЖУЧКО́ВА** Нина Ивановна (28.2.1924, Саратов ш.), мед. тарихчысы, мед. фән. д-ры (1969). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1947), Казанның 7 нче шәһәр хастаханәсе сәламәтлек саклау пунктының баш табибе урынбасары булып эшли. 1949 елдан Казан мед. ин-тының мед. тарихы кафедрасында (1954 тән мед. тарихы курсы булган сәламәтлек саклауны оештыру каф.). 1961 дән Калинин мед. ин-тында шул ук исем. кафедрада. 1969–84 тә Омск мед. ин-тының сәламәтлек саклау кафедрасында. Хезмәтләре Татарстан мед. тарихына карый.

**ҖАББА́РОВ** Руслан Габделрәкыйб улы (21.7.1970, Әлмәт ш.), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), техник фән. канд. (2009). И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть һәм газ академиясен тәмамлый (1992). 1992 елдан (бүленеп) «Татнефть» АҖдә: «Әлмәтнефть» НГДУда оператор, цех инженер-технологы, технол. бүлеге башлыгы урынбасары (2001 гә кадәр), АҖнең инженерлык үзәге директоры (2002 дән). 2001–02 дә «Шешмаойл» АҖнең инженер-технологы. Дәүләт бүләге нефть чыгару процесслары б-н идарә итү һәм оператив контрольдә тоту корпоратив мәгълүмати системасын сәнәгатькә кертү һәм эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 40 ка якын патенты бар. РФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты.

**ҖАМАЛИ́ЕВА** Розалия Семёновна (24.8.1962, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (2000). Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1985), Респ-ка клиник хастаханәсендә эшли. 1987 елдан Казан мед. ун-тының 2 нче акушерлык һәм гинекология кафедрасында. Хезмәтләре экстрагениталь авырулары булган йөкле хатын-кызларда яралгы үсешенең тоткарлану очракларына, авыруны кисәтү һәм дәвалауга карый.

**ҖӘЛӘ́ТОВ** Марат Марс улы (27.3.1964, Әлмәт р-ны Түбән Мактама штп), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), ТРның атказ. нефтьчесе (2005). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлаганнан соң (1986), «Татнефть» АҖдә эшли (бүленеп): «Әлмәтнефть» НГДУында оператор, мастер, цех башлыгы (1994 елга кадәр), АҖнең бүлек башлыгы (1998 гә кадәр), «Баулынефть» НГДУы башлыгы (2012 дән). «Система-Сервис» идарә компаниясе» ҖЧҖ директоры (2008–12). Дәүләт бүләге нефть чыгару процесслары б-н идарә итү һәм оператив контрольдә тоту корпоратив мәгълүмати системасын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 39 патенты бар. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2003). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЗАБО́ТИН** Игорь Ярославич (9.12.1954, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1977), шунда ук эшли, мәгълүматларны анализлау һәм операцияләрне тикшерү каф. профессоры (2011 елдан). Хезмәтләре матем. программалау мәсьәләләрен чишү теориясе һәм алымнарына карый. Итерация күчеше һәм күплекләр аппроксимациясе юнәлешләрен параметризацияләү б-н бәйле рәвештә псевдокалку программалау мәсьәләләрен чишү алымнарын эшли. Радио электрон системаларын проектлау б-н бәйле бер төркем гамәли оптимальләштерү мәсьәләләрен хәл итә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2012).

**ЗАЙКО́ВА** Фәния Мансур кызы (6.9.1956, Якутия АССР, Томпо р-ны Хандыга пос.), табиб педиатр, мед. фән. канд. (2003), ТРның атказ. табибе (2012), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2017). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1980), 1981 елдан Казан шәһәре 8 нче балалар хастаханәсендә: участок табибе, педиатрия бүлеге мөдире (1985), поликлиника эшләре буенча баш табиб урынбасары (1989), баш табиб (1990), бер үк вакытта, 2004 тән, Казан мед. академиясенең балалар неврологиясе кафедрасында. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешен балалар неврологиясе тәшкил итә. Дәүләт бүләге «Балада туу вакытында барлыкка килгән үзәк нерв системасы тайпылышлары. Мультидисциплинар караш, иртә диагноз кую, кисәтү системасы һәм тернәкләндерү этаплары» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЗАКИРҖА́НОВ** Әлфәт Мәгъсүмҗан улы (7.10.1959, Мамадыш р-ны Югары Яке а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2012), Казан пед ин-тын тәмамлый (1983). 1983–90 елларда Мамадыш р-нында урта мәктәп укытучысы, 1990–94 тә Мәскәү милли мәгариф проблемалары ин-тының Казан ф-лында фәнни хезмәткәр һәм гыйльми сәркатип, 1995–2017 дә Казан ун-тында эшли, доцент (1997 дән). 2017 дән ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында, әдәбият белеме бүлеге мөдире. Хезмәтләре татар әдәбияты тарихына һәм теориясенә, татар әдәбияты белеме үсеше мәсьәләләренә карый. Югары уку йортлары һәм гомуми белем бирү оешмалары өчен уку-укыту–методик ярдәмлекләр, ш.у. дәреслекләр авторы һәм автордашы.

ТР Язучылар берлеге әгъзасы (2005). ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең Җ.Вәлиди исем. (2011), ТР Язучылар берлеге һәм Мамадыш р-ны хакимиятенең Ш.Маннур исем. (2019) бүләкләре лауреаты.

**ЗАКИ́РОВ** Илфат Индулис улы (9.2.1970, Ижевск ш. – 14.3.2000,Чечен Респ-касының Урус-Мартан р-ны Комсомольское а., Ижевск ш.ндә җирләнә), РФ Герое (1.3.2001), өлкән лейтенант. Балалар һәм яшьләр спорт мәктәбендә самбо буенча тренер булып эшли. 1988–90 елларда Совет Армиясендә. 1991–2000 дә снайпер, РФ Эчке эшләр министрлыгының (1998 дән РФнең Юстиция министрлыгы) Удмуртия буенча Җәзаларны үтәтү идарәсенең «Кречет» махсус отрядының взвод командиры. Төньяк Кавказдагы законсыз коралы төркемнәргә каршы махсус операцияләрдә катнаша. Комсомольское авылы (Чечен Респ-касының Урус-Мартан р-ны) өчен барган сугышта батырлык күрсәтә. 2000 нең 14 мартында беренчеләрдән булып авылга бәреп керә, авыр яралана, ләкин хезмәттәшләренә эвакуацияләнү мөмкинлеге бирү өчен сугышуны дәвам итә, һәлак була. Ижевскида бер урмага З. исеме бирелә, мемориаль такта куела. Ул укыган 55 нче урта мәктәп Герой исемен йөртә. 2004 тән Ижевскида дзюдо буенча И.И.Закиров призына турнир үткәрелә.

**ЗАКИ́РОВ** Рөстәм Раиф улы (11.5.1967, Арча р-ны Урта Пошалым а.), җырчы, ТРның халык артисты (2014). Казан пед. ин-тының музыка ф-тын тәмамлый (1993). 1993–97 елларда ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы Дәүләт халык музыка уен кораллары ансамбле солисты (сәнгать җитәкчесе Х.Нигъмәтҗанов). 1997 дән Казан шәһәр филармониясендә эшли. З. актив концерт эшчәнлеге алып бара. Татарстанда, Россиядә һәм чит илләрдә (Америка, Австралия, Финляндия, Төркия, Казакъстан, Таҗикстан, Үзбәкстан, Балтыйк буе илләре һ.б.) чыгышлар ясый. Репертуарында «Иске Карурман», «Агыла да болыт агыла», «Өч Пошалым — өч игезәк», «Тәгәрәткән бәрәңге», «Картайма әле, әнкәй», «Йөрәк дәшә» һ.б. җырлар бар. Халыкара «Татар җыры» конкурсы лауреаты, Гран-при иясе (1993). Халыкара «Татар җыры» эстрада фестивале лауреаты (2000, 2001, 2014, 2015, 2017). «Пошалым чаналары» җыр фестиваленә нигез салучы (2004).

**ЗАКИ́РОВ** Шәмси (Шәмсемөхәммәт) Закир улы (11.2.1951, Мамадыш р-ны Шәдче а.), мәдәният эшлеклесе, актёр, юмор остасы, педагог, ТРның халык артисты (2011), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре. Казан мәдәният ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук эшли, 1979–84 тә ТАССР Түбән Кама р-ны мәдәният бүлеге мөдире, 1984–99 да «Нефтехимик» клубы директоры, 1999–2001 дә шәһәр мәдәният йорты директоры, 2002 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында (хәзер Казан мәдәният ин-ты) эшли. З. «Мунча ташы» татар эстрада миниатюралары театрын (Түбән Кама) оештыра һәм җитәкли, «Кыек шәүлә» эстрада театрын оештыра. Актёр буларак Булат («Зөбәйдә — адәм баласы», Ш.Хөсәенов), Тәлгать («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит), Карт («Яучылар», Т.Закиров) һ.б. рольләре б-н таныла.

**ЗАКИ́РОВА** Илсөяр Гамил кызы (9.5.1968, Кама Тамагы р-ны Казиле а.), фольклорчы, филол. фән. д-ры (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1991), Казандагы 137 нче урта мәктәптә эшли, 1998 елдан ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать и-тында. Хезмәтләре төрки халыклар фольклорына, хәзерге татар фольклорына карый.

**ЗАКИ́РОВА** Чулпан Ринат кызы (24.7.1977, Казан), балет артисты, биюче, хореограф, актриса, педагог. ТРның халык артисты (2013). Казан ун-тының юридик ф-тын (1999), Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) балетмейстерлык ф-тын (2004) тәмамлый. 1991–2002 елларда Татар акад. театры актрисасы, бер үк вакытта, 1996 дан, «Казан» муниципаль бию ансамбле биючесе, 2003 тән «Казан» милли мәдәният үзәгенең Казан шәһәр филармониясе составындагы «Казан» бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе. 2009–15 тә Казан ун-тының Филол. һәм мәдәниятара багланышлар ин-тында музыка сәнгате һәм хореография каф. мөдире. З. ялгыз, парлы, төркем б-н бию композицияләре («Чегән сюитасы» («Цыганская сюита»), «Болгар яугирләре биюе» («Танец булгарских воинов»), «Нурлы Казанны саклаучылар» («Защитники светозарной Казани»), «Беренче үбешү» («Первый поцелуй»), «Казан хәзинәләре» («Казанские сокровища»), «Бөек ефәк юл» («Великий шёлковый путь») һ.б.) әзерли. РФ төбәкләрендә һәм чит илләрдә (Испания, Малайзия, Кытай, Тайвань, Австралия һ.б.) ансамбль б-н чыгышлар ясый. Медаль б-н бүләкләнә.

**ЗАРИ́ПОВ** Альберт Марат улы (8.11.1968, Үзбәкстан ССР, Бохара өлкәсенең Бостан пос.), РФ Герое (15.5.1996), өлкән лейтенант. Рязань радиотехника ин-тын (1987), язань югары һава-десант командирлары уч-щесен (1993) тәмамлый. 1987 елдан Совет армиясендә, махсус билгеләнгән 6 нчы батальонның өлкән разведчик-пулемётчысы, Төркестан хәрби округы 40 нчы армиясенең махсус билгеләнгән төркем командиры урынбасары, Әфганстан Респ-касы терр-ясендә хәрби операцияләрдә катнаша. 1993–96 да Төньяк Кавказ хәрби округы Дәүләт разведка идарәсенең махсус билгеләнгән 22 нче аерым бригадасы составында, 1993 нең август-октябрендә Төньяк Осетия Респ-касында гадәттән тыш хәлләр зонасында тыныч халыкны саклауда, 1993 нең декабрендә Ростов шәһәрендә тоткынлыкка алынган мәктәп укучыларын коткару буенча махсус операциядә, ш. у. 1995 нең гыйнварыннан (1995 нең июнендә Будённовск шәһәрендә махсус операциядә) беренче чечен кампаниясендә (1994–96) катнаша. 1996 ның гыйнварында Первомайск авылы (Дагстан Респ-касы) өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: дошман чолганыштагы авылдан чыккан вакытта 2 эре калибрлы племёт расчётын, ш. у. берничә сугышчыны юк итә; Россия солдатларының чигенүен тәэмин итеп, авыр яралана. 1996 дан отставкада. Мәскәүдә яши. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЗАРИ́ПОВ** Марат Наил улы (15.1.1968, Казан), хокук белгече, юстиция генерал-майоры (2015), ТРның атказ. юристы (2007), РФ Тикшерү ком-тының мактаулы хезмәткәре (2016). Казан ун-тын тәмамлый (1994). 1994–2002 елларда Казан шәһәренең Идел буе р-ны прокуратурасында: тикшерүче, өлкән тикшерүче, прокурорның гомуми күзәтчелек буенча ярдәмчесе, өлкән ярдәмчесе, урынбасары (2000 нән). 2002–05 тә ТР прокуратурасының үтерүләрне һәм бандитчылыкны тикшерү бүлеге башлыгы. 2006–11 дә Түбән Кама шәһәре прокуроры. 2011 дән РФ Тикшерү ком-тының ТР буенча Тикшерү идарәсе җитәкчесенең 1 нче урынбасары. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЗАРИ́ПОВ** Радий Ринат улы (5.5.1958, Баулы р-ны Баулы штп), 1 нче ранг капитаны (1997), тарих фән. канд. (2011). Радиоэлектроника югары хәрби-диңгез уч-щесен тәмамлый (Ленинград, 1981). 1981 елдан СССР Хәрби-Диңгез Флотында: 1984–89 да стратегик максатлардагы «К-433», «К-490» ракеталы су асты крейсерлары радиотехник хезмәте башлыгы. 1989–93 тә — СССР (РФ) ДОСААФының Казан диңгез мәктәбе, 1993–98 дә ТР оборона спорт-техник оешмасының Казан техник мәктәбе башлыгы. 1998–2018 дә ТР РОСТОсында (ДОСААФ), Респ-ка Советы (2004–08), Идарә (2008–18) рәисе. Бер үк вакытта, 2009 дан, Казан Архитектура-төзелеш ун-тының тарих һәм филос. каф. доценты. Хезмәтләре Татарстан ирекле оборона оешмалары һәм җәмгыятьләре (ОСОАВИАХИМ, ДОСААФ һ.б.), Бөек Ватан сугышы елларында гаскәри резервлар хәзерләү тарихына карый. ТР Иҗтимагый палатасы (2006–07), Халыкара су асты көймәсендә хезмәт итүчеләр ассоциациясе (2004) әгъзасы. ТРның оборона-техник оешмалары үсешенә зур өлеш кертә. Медальләр, ш.и. 1 нче, 2 нче, 3 нче дәрәҗә «Лаеклы хезмәт иткән өчен» («За безупречную службу») медальләре б-н бүләкләнә.

**ЗАҺИДУ́ЛЛИН** Ленар Рәфыйк улы (8.7.1979, Арча р-ны Пионер а.), галим зоотехник, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013), биол. фән. канд. (2006). Казан вет. медицина академиясен тәмамлаганнан соң (2001), шунда ук механикалаштыру кафедрасында эшли. Дәүләт бүләге ТРда сөт терлекчелеге тармагы нәтиҗәлелеген күтәрүдә инновацион технологияләр кертүне эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ЗАҺИДУ́ЛЛИН** Рәшит Зиннәт улы (26.10.1950, Казакъстан ССР, Алма-Ата өлкәсе Панфилов ш. (1991 дән Жаркент ш.)), филолог, филол. фән. д-ры (1994), проф. (2000), Казакъстан Респ-касының мәгариф отличнигы (1998). Алма-Ата чит телләр пед. ин-тын (1971), Морис Торез исем. Мәскәү чит телләр ин-тының югары пед. курсларын (1978) тәмамлый. 1971 елдан Караганда мед.

ун-тында: 1971, 1973–76 да өлкән лаборант, телләр кафедрасында укытучы, 1978 дән чит телләр кафедрасында укытучы, өлкән укытучы, доцент, 1985–90 да чит телләр каф. мөдире. 1994 тән Абылай хан исем. Казакъ халыкара мөнәсәбәтләр һәм дөньяви телләр ун-тының инглиз теленнән тәрҗемә каф. доценты, мөдире, профессоры, бер үк вакытта, 1995 тән, ун-т каршындагы Мәдәниятара коммуникация һәм тәрҗемә проблемалары буенча фәнни-тикшеренү үзәге лаб-ясе мөдире. 2006 дан Казакъстан-Британия ун-тында: телләр һәм гуманитар фәннәр каф. профессоры (2009 дан). Инглиз теле терминологиясен һәм лексикографиясен өйрәнүгә, тәрҗемә, укыту ысулларын өйрәтүгә зур өлеш кертә. Америка хәзерге заман телләре ассоциациясе (Modern Language Association of America, 2002 дән), Казакъстан Фулбрайт программасын тәмамлаучылар ассоциациясе (Fulbrait Association of Kazakhstan, 2003 тән) әгъзасы. Австралия, Азия (Һиндстан, Япония), Америка (Канада, АКШ), Африка (Мисыр), Европада (Австрия, Бөекбритания, Германия) узган конгрессларда һәм конференцияләрдә катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЗАҺИ́ТОВА** Алинә Илназ кызы (18.05.2002, Ижевск ш.), спортчы (фигуралы шуу). Россиянең атказ. спорт остасы (2018). Спорт б-н 2007 елда Әлмәт шәһәрендә шөгыльләнә башлый. 2008–2014 тә Ижевск шәһәренең Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер Н.Антипинада шөгыльләнә. 2015 тән «Самбо-70» спорт һәм мәгариф үзәгендә тәрбияләнә (Мәскәү, тренерлары — Э.Тутберидзе, С.Дудаков, Д.Глейхенгауз). 2017 дә Гран-при финалында җиңүче һәм көмеш медаль иясе. Яшүсмерләр арасында дөнья (2017), Россия (2018) чемпионы. Олимпия уеннарында команда ярышларында көмеш, ялгыз шууда алтын медальләр (Пхёнчхан, 2018), Европа чемпионатында ялгыз шууда алтын (Мәскәү, 2018) һәм көмеш (Минск, 2019) медальләр ала. Дөнья чемпионатында ялгыз шууда алтын медаль (Сайтама, Япония, 2019) яулый. Дуслык ордены б-н бүләкләнә.

**ЗӘБИ́РОВ** Рөстәм Мөхәммәт улы (7.6.1961, Казан), архитектор, ТРның атказ. архитекторы (2011). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), «Казжилремпроект» проектлау конторасында архитектор, 1986–94 елларда «Казгражданпроект» ин-тында, 1995–96 да «АССАРТ» җаваплылыгы чикләнгән ширкәтендә баш архитектор, 1996 дан «Казан Кремле» музей-тыюлыгында баш архитектор. Бер үк вакытта, 1993 тән, «Зәбир» шәхси иҗат остаханәсендә реставрация проектлары баш архитекторы. З. проектлары буенча Казан Кремлендәге Тупчылар утарының төньяк, төп (көнчыгыш) һәм төньяк корпуслары (автордаш), утардагы төп корпусның Гербы залы интерьерлары (автор), Кол Шәриф мәчете ансамбле (1997–2005, автордаш, 2012 дә ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек була), ш. у. Горький урамындагы Кекин йорты (автордаш) реставрацияләнә. Казан Кремлендәге 15–16 йөзләргә караган Хан утары комплексындагы вәкиллек бинасы, мәчет бинасы калдыклары консервацияләнә һәм музейлаштырыла (автор); Кремльдәге Казан ханнары сөякләре күмелгән мемориаль павильонның эскиз проектын (автор), Әстерхан шәһәрендәге «Ак мәчет» (2008, автордаш) һәм Самара шәһәрендәге мәчет (2009, автордаш) интерьерларын эшли. Архитекторлар берлеге (1994), Һәйкәлләрне һәм тарихи урыннарны саклау буенча халыкара советның (ICOMOS) Россия милли ком-ты әгъзасы (1998). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЗӘЙНИ́ЕВ** Илгиз Газинур улы (23.5.1987, Аксубай р-ны Карасу а.), драма актёры, режиссёр, драматург. ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2019). Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тының актёрлык (2008) һәм режиссёрлык (2013) ф-тларын тәмамлый. 2008–19 елларда Татар акад. театрында: актёр, режиссёр. Театр сәхнәсендә Булат («Зөбәйдә — адәм баласы», Ш.Хөсәенов), Дәүләт («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт) һ.б. рольләрне башкара. Беренче пьесасы — «Җәйге төннәрдә» (2002). Татар акад. театрында З.нең «Мәхәббәт турында сөйләшик», «Бәби», «Люстра», «Көтәм сине», «Бабайлар чуагы», «Мәхәббәт FM», «Әрем исе», «Кечтүкле уен», «Кәҗә, Сарык һ.б.», «Суган чәчәге» һ.б. пьесалары буенча спектакльләр куела. З. пьесалары ш.у. Әлмәт, Оренбург, Туймазы, Йошкар-Ола, Алма-Ата шәһәрләренең драма театрларында сәхнәләштерелә. Аның сәхнә әсәрләренә лириклык, психол. төгәллек, нечкә юмор хас. Режиссёр буларак куйган спектакльләре: «Галиябану» (М.Фәйзи), «Үлеп яратты» (Р.Зәйдулла), «Ричард III» (У.Шекспир), «Бармы ришвәттән дәва?» (З.Хәким), «Качаклар» («Һиҗрәт» пьесасы буенча, Н.Исәнбәт), «Мәңгелек буран» (Ч.Айтматов). 2019 дан Татар «Әкият» курчак театрының баш режиссёры. ТР Язучылар берлеге (2007) һәм ТР Театр эшлеклеләре берлеге (2012) әгъзасы. М.Җәлил исем. Респ-ка бүләге лауреаты (2009).

**ЗӘЙНИ́ЕВ** Роберт Мәхмүт улы (29.7.1946, Сарман р-ны Сарман а.), математик, педагог, физика-матем. фән. канд. (1979), пед. фән. д-ры (2012). Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1969), 1971 елдан шунда ук матем., матем. анализ кафедраларында эшли (1976 дан), 1980 нән физика-матем. ф-ты деканы. 1984 тән Чаллы пед. ин-тының пед. кафедрасында, 1985 тән сәнгать-графика ф-ты деканы, 1987 дән башлангыч белем бирү методикасы кафедрасында, 1990 нан матем. ф-ты деканы, 1993 тән проректор. 1998 дән Кама политехник ин-тында (2013 тән — Казан ун-тының Чаллы ин-ты): проректор, 1999 дан югары матем. кафедрасында (бүленеп, 2006–2011 дә ректорның халыкара эшчәнлек буенча ярдәмчесе), 2013 тән матем. каф. профессоры. Хезмәтләре нәсызыкча сингуляр интеграль тигезләмәләр теориясен куллануга, инженерлык-техник белемнең һөнәри юнәлтелгән эчтәлегенә карый.

**ЗӘКӘМУ́ЛЛИНА** Миләүшә Нурулла кызы (3.12.1951, Буа р-ны Әлши а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2001), проф. (2001), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2014). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1974). 1974–75 елларда Лениногорск р-ны Зәй-Каратай урта мәктәбендә укыта, 1975–76 да Казан «Вакууммаш» фәнни-тикшеренү ин-тында тәрҗемәче. 1976–2001 дә — Казан пед. ин-тында (бүленеп, 1977–79 да В.И.Ленин исем. Мәскәү пед. ин-тында чит телләр ф-тының Югары пед. курслары тыңлаучысы). 2001 дән Казан энергетика ун-тында чит телләр каф. мөдире, профессоры. Хезмәтләре вакытлы референциянең лингвокогнитив мәсьәләләре, референция һәм кореференция теориясе яктылыгында төрле төзелешле телләр темпораль-аспектуаль системаларының функциональ һәм прагматик үзенчәлекләре, лингвополитология, глоттополитика, француз теленең трансчиктәш, Квебекның глоттогенез һәм демотел мәсьәләләренә карый. Француз теленең грамматик үзенчәлекләрен яктырткан уку-укыту–методик ярдәмлекләр авторы. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2010).

**ЗӘКУА́НОВ** Рөстәм Газизҗан улы (25.5.1957, Азнакай р-ны Үчәлле а. – 2.12.2018, Казан, Биектау р-ның Мүлмә авылында җирләнә), журналист, шагыйрь, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан сон (1980), «Уразман» к-зы рәисе урынбасары (1980–85), «Янтарь» с-зы директоры (1985), «Татнефть» берләшмәсенең эшчеләрне тәэмин итү идарәсе директоры урынбасары (2000–01). 2001–04 елларда Азнакай р-ны башлыгы урынбасары. ТР Дәүләт Советы депутаты (2004–09). 2009 дан «Таттелеком» АҖнең матбугат хезмәте җитәкчесе. Мәктәптә укыган елларда ук аның хезмәт кешеләре турындагы беренче мәкаләләре «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй») һәм районның «Маяк» г-таларында басыла башлый. «Социалистик Татарстан» (хәзер «Ватаным Татарстан»), «Татарстан яшьләре» һ.б. газеталарда аның дистәләрчә язмалары дөнья күрә. З. шигырьләрендә, бай тормыш тәҗрибәсенә нигезләнеп, татар халкының фаҗигале тарихын, авыл кешесенең каршылыклы кичерешләрен тирәнтен тоеп, фәлсәфи бәяли. Аның шигырьләре туган якка чиксез мәхәббәт белән сугарылган. Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2018), ТР Язучылар берлеге әгъзасы (2007).

**ЗВЕ́РЕВ** Владислав Васильевич (23.1.1941, Киров өлкәсенең Тужа р-ны Тужа а.), химик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010), химия фән. канд. (19680. Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң (1963), Казан химия-технол. ин-тында эшли. 1968 елдан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында. Хезмәтләре фенилбензол кушылмалары квант химиясе, азот, фосфор, кислород һәм күкерт органик кушылмаларының фотоэлектрон спектроскопияләре, гидразоннар төзелеше һәм нигезләре мәсьәләләренә, фуллерен чыгарылмаларының төзелешен һәм үзенчәлекләрен фаразлауга карый. Дәүләт

бүләге «Фуллереннарның органик чыгарылмалары — электроника һәм биомедицина өчен наноматериаллар булдыруда төзелеш блоклары» хезмәтендә катнашканы өчен бирелә.

**ЗЕКРИ́СТ** (Еникиева) Рида Ирек кызы (1.12.1965, БАССРның Баймак р-ны Темәс а.), философ, педагог, филос. фән. д-ры (2017), проф. (2013), РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2016). Ленинград ун-тын тәмамлый (1989). 1989–91 елларда Кустанай пед. ин-тында укыта. 1991 дән Кустанай яшьләр эшләре, туризм һәм спорт идарәсендә өлкән, әйдәп баручы белгеч. 1995–2005 тә Рудный индустрия ин-тының социаль-гуманитар фән. кафедрасында өлкән укытучы, доцент (Кустанай өлкәсе). 2006 дан Чиләбе ун-тының Кустанай ф-лында директор урынбасары, фәнни-тикшеренү эшләре бүлеге мөдире, социаль-гуманитар фәннәр каф. доценты. 2013 тән З.Алдамжар исем. Кустанай социаль-техник ун-тында гуманитар фән. каф. профессоры. Хезмәтләре хакимият феноменының асылын һәм глобализация шартларында аның шәхес эшчәнлегенә йогынтысының социаль-тарихи формаларын өйрәнүгә, социаль идарәнең методологик һәм теоретик мәсьәләләренә, мәдәни үзбилгеләнү фәлсәфәсенә карый. Татар-башкорт милли-мәдәни «Дуслык» үзәге, Казакъстан халыклары ассамблеясының Кустанай татар-башкорт берләшмәсе каршындагы фәнни-экспертлар төркеме әгъзасы, Рус филос. җәмгыятенең башлангыч оешмасы рәисе (Кустанай ш.). Медаль б-н бүләкләнә.

**ЗЕФИ́РОВА** Татьяна Петровна (19.9.1956, Куйбышев ш.), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (2008). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1979). 1980 елдан Казан мед. академиясенең акушерлык клиникасында, 1988 дән 1 нче акушерлык һәм гинекология кафедрасында, каф. профессоры (2010). Хезмәтләре бала тудыру эшчәнлеге сүлпәнлеген көйләүгә, урогениталь инфекцияләрне дәвалау ысулларын өйрәнүгә, авыруларны энә б-н дәвалауга карый. Уйлап табуга патенты бар.

**ЗИННӘТУ́ЛЛИНА** Гөлнара Хабул кызы (7.4.1952, Лаеш р-ны Хәерби а.), телевидение журналисты, мөхәррире һәм алып баручысы. ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). Казан ун-тын (1982) тәмамлый. 1970 елдан Казан телестудиясендә режиссёр ярдәмчесе һәм балалар тапшырулары алып баручы. 1972 дән әдәби-драматик тапшырулар редакциясендә режиссёр ярдәмчесе. 1980 нән балалар тапшырулары мөхәррире һәм алып баручысы («Пионерстан», «Без авылда яшибез», «Мәйданга чыгыгыз, батырлар», «Күңелле уеннар», «Бергәләп өйрәник», «Әлли-бәлли-бәү», «Шигъри тәлгәшләр»). 1991–94 елларда «Чулпан» программасын алып бара. 1994 тән авторлык программаларын булдыра: «Түрдән узыгыз», «Иртә түгел, соң түгел», «Шәрәфигә ияреп», «Яшәсен театр!» (ТНВ фондында саклана), «Яшәү яме». «Иртә түгел, соң түгел» һәм «Яшәү яме» тапшырулары цикллары өчен «Бәллүр каләм» («Хрустальное перо») бәйгесе дипломы белән бүләкләнә (2000, 2007). «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең туры эфирда Җиңү бәйрәменә, Респ-ка көненә, Сабан туена һ.б.га багышланган тапшыруларны алып бара.

**ЗИНОВЬЕВ** Владимир Николаевич (23.11.1951, Әлмәт ш. — 2.4.2010, шунда ук), төзүче инженер, РФнең атказ. төзүчесе (2003), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010, вафатыннын соң). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1980). 1971–92 елларда (бүленеп) Әлмәт шәһәрендәге төзелеш оешмаларында: «Татспецстрой» трестының төзелеш-монтаж идарәсе (1980 нән), «Татнефтепроводстрой» ЖБнең төзелеш-монтаж тресты (1991 дән) баш инженеры. 1976–80 дә КПССның Әлмәт шәһәр ком-ты инструкторы. 1984–91 «Якутгазпром» ЖБдә механикалаштырылган колонна баш инженеры, төзелеш-монтаж идарәсе башлыгы. 1992 дән «Татанефть» АЖдә: «Ямашнефть» НГДУ башлыгының, АЖ директорының (2010 нан) капиталь төзелеш буенча урынбасары. Дәүләт бүләге нефтьне промыселдан транспортлауның ышанычлылыгын арттыруны технол. яктан хәл итү комплексын тикшерү һәм сәнәгатьтә гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЗИНУ́РОВА** Раушания Илшат кызы (18.10.1966, Саба р-ны Байлар Сабасы а.), социолог, социол. фән. д-ры (2005), проф. (2008). Казан ун-тын (1988), РМАның Һөнәри белем бирү пед. һәм психол. ин-тын (1996), Россия дәүләт социаль ун-тын (2006) тәмамлый. Казан пионерлар сараенда (1988–1990), Чистай «Вектор» конструкторлык-техник бюросында (1990–93), Чистай мәгълүмат пр-тиесендә (1993–97), Казан техник ун-тында (1997), Казан социаль-юридик ин-тында (хәзер Социаль белем бирү академиясе, 1997–2005) эшли, 2005 тән Казан технол. ун-тында. Татарстан Респ-касының Яшьләр эшләре министрлыгында фәнни-методик совет әгъзасы (2018 дән). «Управление устойчивым развитием» ж-лының баш мөхәррире (2015 тән). Хезмәтләре социол. һәм этносоциол. мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга патенты бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2015). Медаль б-н бүләкләнә.

**ЗИ́НЧЕНКО** Сергей Викторович (16.6.1975, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (2011). Казан мед. ун-тын тәмамлый (1998). 1999–2000 елларда Казан ясалма каучук з-дының мед.-сан. частенда эшли. 2001 дән Респ-ка онкология клиник диспансерының балалар хирургиясе бүлегендә табиб-онколог. Бер үк вакытта, 2011 дән, Казан мед. академиясенең клиник онкология кафедрасында. Хезмәтләре үпкәдәге вак күзәнәкле рак авыруын өйрәнү, аны дәвалау ысулларын эшләүгә карый.

**ЗОЛОНДИ́НОВ** Әмир Таһир улы (2.12.1951, Казан), кинооператор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2002). Бөтенсоюз кинематография ин-тын тәмамлый (1991, Мәскәү). 1975 елдан Казан кинохроника студиясендә: оператор ярдәмчесе, катнаш төшерүләр операторы, оператор-куючы. 30 дан артык документаль фильм, ш.и. «Алабуга» (1993), «Күпер» («Мост», 2000), «Кави Нәҗми» (2002), «Академик Мансур Хәсәнов» (2003) фильмнарын, ш.у., оператор-куючы буларак, «Шайтан курчаклары» («Чёртовы куклы»), «Зөләйха» фильмнарын төшерә. РФнең мактаулы кинематографисты (2001).

**ЗЫЯКА́ЕВ** Әхнәф Гаделгәрәй улы (9.11.1956, БАССРның Нефтекама ш.), скульптор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2011). Көнгер таш уюу уч-щесен (1983), И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын (1994) тәмамлый. 1980 еллардан С.-Петербургта яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1994). Л.Н.Гумилёвка (1997), Г.Тукайга, М.Җәлилгә (2000 еллар) мемориаль такталар, С.-Петербургта «Конка» (2005), Г.Тукай (2009, автордашы Я.Нейман), М.Җәлил (2011, автордашы Я.Нейман) бронза һәйкәлләре; Ашхабад шәһәрендә (Һиндстан, 1998) фонтан (бронза, пыяла, йөгертелгән алтын), Белгород өлкәсенең Старый Оскол шәһәрендә А.С.Пушкин һәйкәле (1999) һ.б. авторы. Әсәрләре Рус музеенда (С.-Петербург), «Казан» милли мәдәният үзәгендә, шәхси тупланмаларда саклана.

**ЗЫЯТДИ́НОВА** Нәфисә Илгиз кызы (3.5.1975, Түбән Кама ш.), физиолог, биол. фән. д-ры (2015), проф. (2016). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1997). 1997–99 елларда Татар гуманитар ин-тының иҗтимагый фәннәр каф. ассистенты, бер үк вакытта, 1998–2001 дә, Казан пед. ун-тының анатомия, физиол. һәм кеше сәламәтлеген саклау каф. аспиранты. 2001–03 тә — Казан мед. ун-тының нормаль физиол., 2003–16 да Казан ун-тының (КФУ) анатомия, физиол. һәм кеше сәламәтлеген саклау кафедраларында. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре физиологиягә, постнаталь онтогенезда йөрәк эшчәнлеген көйләүгә карый. «Россия профессорлар җыены» иҗтимагый оешмасы әгъзасы.

**ИБРАҺИ́МОВ** Данил Исмәгыйль улы (18.11.1949, Арча р-ны Иске Кырлай а.), тарихчы, тарих. фән. канд. (2009), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1999), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1983). 1972–82 елларда Казан мәдәният йортларында концертмейстер. 1982–93 тә «Татарстан» ДТРКда: радиотапшырулар директоры, бүлек мөдире (1987–93). 1993–96, 2001–05 тә ТР МК аппаратында референт. 1996–2001 дә ТР Премьер-министры урынбасары ярдәмчесе. 2005–15 тә ТР МК каршындагы Баш архив идарәсе башлыгы. Хезмәтләре Татарстанда архив эше тарихына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ИБРАҺИ́МОВ** Рафаил Локман улы (15.11.1953, Курск ш.), гидрогеолог, геол.-минерал. фән. д-ры (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), ТатНИПИнефтьтә эшли. 2007 елдан Татарстан геол.-разведкалау идарәсендә, гидрология буенча баш гео-

лог урынбасары (2010 нан). Хезмәтләре нефть промыселлары гидрогеологиясенә, төче һәм дәвалау суларын эзләүгә карый. Нефть ятмаларының сакланганлык дәрәҗәсен бәяләү алымнарын эшли, нефть ятмаларын типологик районлаштыру үткәрә, эш процессында нефть ятмаларының тотрыклылык шартларын билгели, җир асты суларын гидроминерал. чималы сыйфатында һәм бальнеология максатларында файдалану мөмкинлеген ачыклый.

**ИБРАҺИ́МОВ** Тимур Франил улы (7.9.1988, Чиләбе өлкәсенең Брединск р-ны Светлые Озёра пос. – 20.3.2009, Дагстан Респ-касының Карабудахкент р-ны Какашура а.; Чиләбе өлкәсенең Боровое авылында җирләнә), РФ Герое (7.7.2009, үлгәннән соң), рядовой. 2007 елда 8 кешелек гаиләне янгыннан коткара. 2008 дән РФ Хәрби Көчләрендә, РФ Эчке эшләр министрлыгы Себер региональ эчке гаскәрләр командованиесенең 27 нче махсуслашкан «Кузбас» отрядының штурмлау отделениесе укчысы. 2009 ның 20 мартында Дагстан Респ-касының Карабудахкент р-ны Какашура авылы тирәсендә разведка-эзләү чаралары үткәрү вакытында батырлык күрсәтә: махсуслашкан отряд дошманның кораллы төркеменә юлыга, ике арада сугыш башлана; яраланган командирны сугыш кырыннан алып чыкканда, снайпер тарафыннан үтерелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ИБРАҺИ́МОВА** Наилә Нургазиз кызы (5.8.1945, Тукай р-ны Ябынчы а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2010). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1968), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Башта травести актриса буларак чыгыш ясый, яшүсмерләрнең якты образларын иҗат итә: көлкеле, үзенчәлекле характерлы Эльвира («Туй алдыннан», Х.Вахит), җитез, кызыксынучан Малай («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), шук, хәйләкәр Фаншетта («Фигароның өйләнүе», П.Бомарше), язмыш сынаулары иртә җитлектергән Лялька («Бер төн», Б.Л.Горбатов), Садри («Галиябану», М.Фәйзи), Әнәс («Ике килен-килендәш», Х.Вахит), Бибигайшә («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт). Алга таба драматик һәм кискен характерлы рольләр И.ның иҗат диапазоны киңәйтә. И. башкаруында өметсезлеккә бирелгән Алтынчәч («Әниләр һәм бәбиләр», Т.Миңнуллин), саф күңелле Гөлбану («Татар хатыннилар күрми», Г.Ибраһимов), мәгънәсез Элен («Гауганы гаилә», Э.де Филиппо) үзенчәлекле, кабатланмас образлар буларак аерылып тора.

**ИБРАҺИ́МОВА** Фагыйлә Нурулла кызы (7.3.1926, Төмән өлкәсенең Төмән р-ны Талмы (Есаулово) а. — 7.9.2010, шунда ук), сыер савучы, Соц. Хезмәт Герое (1973). Хезмәт юлын Бөек Ватан сугышы елларында колхозда төрле эшләр эшләп башлый. 1946 елдан сыер савучы. Герой исеменә терлекчелек өлкәсендәге казанышлары өчен лаек була: 1968, 1972, 1973 елларда, тиңдәшле рәвештә, һәр сыердан елына 3200, 4546, 4031 *кг* сөт савып ала. СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә катнаша, КПССның XXV съезды делегаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 нче, 3 нче дәрәҗә Ана даны орденнары (9 ир бала үстерә, шуларның берсе уллыкка алынган). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ИДРИ́СОВ** Рөстәм Фидай улы (10.11.1962, Ульянов ш.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2002). СССР Эчке эшләр министрлыгының Эчке гаскәрләр югары сәяси уч-щесен тәмамлый (С.-Петербург, 1991). 1991–93 елларда С.-Петербургның Эчке эшләр баш идарәсендә бүлек башлыгы. 1996–98 дә РФ Эчке эшләр министрлыгының Петербург ин-тында укыта. 1999–2000 дә идарә башлыгы урынбасары – РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь комплекс буенча дәүләт ком-ты Баш дәүләт торак инспекциясе бүлеге башлыгы (Мәскәү). 2001–02 дә Россия Гади кораллар буенча структур үзгәрешләр һәм региональ сәясәт идарәсе бүлеге башлыгы. 2003–04 тә РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык дәүләт ком-тының хокук идарәсе башлыгы. 2004–09 да РФАнең Иминлек проблемаларын өйрәнү үзәге директоры урынбасары. 2009–11 дә Удмурт Респ-касы, 2011–13 тә ТР буенча баш федераль инспектор. 2016 дан РФАнең Иминлек проблемаларын өйрәнү үзәге директоры. Хезмәтләре РФдә иминлек тәэмин итүнең теоретик һәм хокукый мәсьәләләренә карый.

**ИЖБУЛА́ТОВ** Рөстәм Хаҗиәхмәт улы (29.10.1905, Уфа губ. Новосёловский волосте, хәзер БРның Благовар р-ны Өйдерәкбаш а. – 16.04.1938), хәрби җитәкче, 3 нче ранг капитаны. Х.И.Ижбулатовның улы. Севастополь Югары диңгез командирлары уч-щесен тәмамлый. Кара диңгез флоты су асты көймәләре 1 нче бригадасының 2 нче дивизионы командиры. Репрессияләр корбаны. 1937 елда «армиядә хәрби-фашистик заговорда катнашучы» буларак кулга алына, атылуга хөкем ителә. Үлгәннән соң аклана.

**ИКСА́НОВ** Анатолий Геннадьевич (Таһир Гаделҗан улы) (18.2.1952, Ленинград ш.), театр эшлеклесе, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1994), Украинаның атказ. сәнгать эшлеклесе (2004), икътиад фән. канд. (2006). Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тын тәмамлый (1977). 1978–83 елларда Ленинград Зур драма театрында баш администратор, 1983 тән директор урынбасары, 1996 дан директор. 1998–2000 дә «Культура» телеканалының ген. директор урынбасары, 2000–13 тә Мәскәүдә Россия дәүләт акад. Зур театры директоры. «Зур драма театры хәйрия фонды: Уңыш теориясе һәм практикасы» («Благотворительный фонд БДТ: Теория и практика успеха», Л., 1997), «Базар икътисады шартларында мәдәният учреждениеләрен ресурс белән тәэмин итү» («Ресурсное обеспечение учреждений культуры в условиях рыночной экономики», М., 2008) һ.б. китапларның автордашы. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**ИКСА́НОВ** Хәйдәр Вазыйх улы (11.4.1961, Лаеш р-ны Татар Сараланы а.), терапевт, мед. фән. д-ры (2009), ТРның атказ. табибе (2004). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1984). 1985 елдан Сарман авылында район үзәк хастаханәсендә эшли, 1997 дән ТР Социаль-тәэминат министрлыгының Респ-ка эшкә яраклылыкны тикшерү мед. комиссиясе рәисе, 2005 тән ТР буенча мед.-социаль экспертиза баш бюросы учреждениесенең баш эксперты, 2006 дан Казан мед. академиясенең реабилитология, спорт һәм мед. кафедрасында. Хезмәтләре инвалидларны комплекслы тернәкләндерү системасы, ятим балалар сәламәтлеген саклау мәсьәләләренә карый.

**ИЛДАРХА́НОВА** Флюра Әмир кызы (10.2.1949, Сарман р-ны Сарайлы а.), социолог, социол. фән. д-ры (2004), ТАССРның атказ. укытучысы (1980), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2012). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1971). 1971–76 елларда Казан шәһәренең 59 нчы мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта, сыйныфтан һәм мәктәптән тыш эшләрне оештыра, 1976–77 дә — ВЛКСМның Киров райкомы (Казан), 1977–82 дә Татарстан өлкә ком-ты секретаре, 1982–84 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире урынбасары. 1994–98 дә ТР мәгариф министры урынбасары, 1998–99 да ТР Мәгариф министрлыгының югары һәм урта махсус уку йортлары бүлеге башлыгы, 1999–2007 дә ТР МКның Гражданлык халәтен теркәү идарәсе (ЗАГС) башлыгы, бер үк вакытта, 2001–07 дә, РМАнең ТР буенча Гаилә һәм тәрбия фәнни-тикшеренү ин-ты өлкән фәнни хезмәткәре. 2007–18 дә ТР ФАнең Гаилә һәм демография фәнни-тикшеренү үзәге директоры. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре ТРда демографик процессларны өйрәнү, «Татарстан гаиләсе» гражданлык халәтен теркәү максатчан программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру, гаиләдә әхлакый яңарыш мәсьәләләренә карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ИЛДАРХА́НОВА** Чулпан Илдус кызы (30.1.1981, Казан), социолог, социол. фән. д-ры (2016). Казан ун-тын тәмамлый (2002). 2002–03 елларда Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында чит телләр каф. ассистенты, 2003–10 да Мәскәү гуманитар ун-тында социол. каф. доценты, 2008–09 да «Махон Хамеш» ун-тында (Мәскәү) инглиз теле укытучысы, 2006–11 дә Россия дәүләт гуманитар ун-тында социол. теориясе һәм тарихы каф. доценты, 2011 дән ТР ФАнең Гаилә һәм демография үзәгендә: баш фәнни хезмәткәр, директор (2018 дән). Халыкара социол. (2014–18), Төрки дөнья социологлары (2017 дән) ассоциацияләре әгъзасы. Хезмәтләре яшьләр, гаилә, авыл, мәгариф социологиясе, демография мәсьәләләренә карый.

**ИЛСА́Ф** (псевд., чын исем-фамилиясе Сафин Илсур Җәмил улы) (9.5.1966, Чүпрәле р-ны Яңа Кәкерле а.), җырчы. ТРның халык артисты (2017). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1991). 1996–97 елларда Татар филармониясендә эшли. 1997 дән «ИлСАФ» җыр сту-

диясе җитәкчесе. Ш. актив концерт эшчәнлеге алып бара. Репертуарында «Тәрәзәләр — әни күзләре», «Әбиләр чуагы», «Кайталар кыр казлары», «Игезәкләр җыры», «Гомерләр бергә узсын», «Хыял», «Азамат» (башкорт халык җыры), «Зәңгәр күлмәк» (Г.Рәхимкулов репертуарыннан) һ.б. җырлар бар. Халыкара Алтын Барс бүләге (2000, 2001, 2004, 2009), «Болгар радиосы» милли музыка бүләге (2015, 2018) лауреаты. Медаль б-н бүләкләнә.

**ИСА́НОВА** Вәлидә Адим кызы (31.3.1942, Әстерхан өлкәсенең Володаровка р-ны Володаровка пос.), невропатолог-реабилитолог, мед. фән. д-ры (1997), проф. (2000), ТРның атказ табибе (1995). Әстерхан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1966), Кабарда-Балкар Респ-касының Александровская станицасы участок хастаханәсе баш табибе, 1976 елдан КПСС ҮКның Нальчик санаторие табибе. 1984 тән Казанда, 2 нче Респ-ка клиник хастаханәсендә табиб-ординатор, бер үк вакытта дәвалау физкультурасы бүлеге мөдире. 1990–97 дә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка инвалид балаларны тернәкләндерү үзәге баш табибе, бер үк вакытта, 1995 тән, Казан мед. ун-тының неврология, нейрохирургия һәм мед. генетикасы каф. ассистенты; 2000 нән неврология һәм нейрохирургия каф. профессоры. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлеше хәрәкәт һәм когнитив тайпылышлы авырулар нейрореабилитациясенә карый, «Атлант» нейро-ортопедик тернәкләндерү пневмокостюмы җайланмасында кинезотерапия методикасы авторы. Англия, Германия, Кытайның халыкара тернәкләндерү үзәкләрендә стажировка үтә. Россиянең төрле төбәкләрендә, Чехия, Польша, Эстония, Казакъстанда реабилитологлар өчен үз авторлык ысулы курслары уздыра. Үз белгечлеге буенча халыкара конференцияләрдә катнаша (Оксфорд, 2017; Рим, 2018). 1997 дән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш нейрореабилитологы. Уйлап табуга 4 патенты бар. Бөтенроссия неврологлар җәмгыятенең идарә әгъзасы.

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВА** Люция Николаевна (21.9.1948, Казан), виолончелист, педагог, ТРның халык артисты (2005). 1973 елда Казан консерваториясен тәмамлый (А.Хәйретдинов классы). 1973–98 дә камера ансамбле иллюстраторы, Казан консерваториясендә виолончель классы буенча укыта. Бер үк вакытта, 1995–2005 тә, 1 нче балалар музыка мәктәбендә, 1991 дән Кече сәнгать академиясендә, 1993 тән Казан музыка көллиятендә укыта. И. шәкертләре арасында симф. оркестрлар артистлары һәм Россиядәге, чит илләрдәге музыка уку йортлары укытучылары, халыкара, бөтенроссия һәм региональ музыкант-башкаручылар конкурслары лауреатлары һәм дипломантлары бар (С.Приходцев, Ю.Крепак-Якимочева, М.Спиридонов, В.Каинов, А.һәм М.Саковец, А.Латыйпова, В.Колупаев, К.Шәрәфетдинов һ.б.). Методик хезмәтләр, кыллы музыка уен кораллары ансамбльләре өчен күчермәләр авторы, музыкант-башкаручылар конкурсларында жюри эшендә катнаша. Солист һәм ансамбльдә чыгыш ясаучы буларак актив концерт эшчәнлеге алып бара, музыка фестивальләрендә катнаша, Россиядә һәм чит илләрдә (АКШ, Германия, Румыния, Төркия, Франция һ.б.) мастер-класслар үткәрә. «Париж-Казан-Транзит» (1996), «XXI йөз талантлары» («Дарования XXI века», Рымникул-Вылчев ш., Румыния, 1999) һ.б. халыкара конкурслар лауреаты һәм дипломанты.

**әл-ИСТАХРИ́** Әбү Исхак әл-Фариси (10 йөзнең 1 яртысы), гарәп географы һәм сәяхәтчесе. Урта, Көньяк һәм Көнчыгыш Азия илләрендә, Сицилия һәм Андалусияда була. Күп кенә мөселман илләрен тасвирлаган «Китабел-мәсаликел-мәмалик» («Дәүләтләрнең юллары турында китап», якынча 930–33) әсәре авторы. Аны язганда гарәп географы әл-Бәлхинең мәгълүматларын, шәхси күзәтүләрен һ.б. чыганакларны файдалана. Әсәрдә Идел елгасы, Болгар, Суар шәһәрләре турында мәгълүмат китерелә; болгарларның кыш көне «агач корылмаларда», җәй көне «чатырларда» яшәүләре әйтелә.

**ИХСА́НОВ** Рәфыйк Рәшит улы (27.9.1965, БАССРның Әлшәй р-ны Түбән Әүрез а.), РФ Герое (21.4.2000), подполковник. Саратов югары хәрби очучылар уч-щесен (1986), Ю.А.Гагарин исем. Хәрби-һава академиясен (Мәскәү өлкәсе Монино штп, 1995) тәмамлый. 1982 елдан СССР Кораллы Көчләрендә. Төркестан, Кавказ алды, Төньяк Кавказ, Себер һәм Мәскәү хәрби округларында хезмәт итә. Әфганстан Респ-касында һәм Төньяк Кавказда сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Герой исеме беренче (1994–96) һәм икенче (1999–2009) чечен кампанияләрендә Төньяк Кавказ регионында законсыз хәрби төзелмәләрне юк итүдә һәм террорчылыкка каршы операцияләрдә күрсәткән батырлыгы өчен бирелә; вертолёт эскадрильясе командиры. 2006 дан запаста. 2007 дән Генерал Е.Н.Кочешков исем. Сов. Союзы һәм РФ Геройларына ярдәм итү фонды вице-президенты (Мәскәү). 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**КАБЫ́ТОВ** Пётр Серафимович (20.6.1941, Воронеж өлкәсе Колодезная ст.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1984), проф. (1985). РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1972 елдан Самара ун-тында: Россия тарихы каф. мөдире (1983 тән), 1 нче проректор (1994–2011), ректор киңәшчесе (2011 дән). Хезмәтләре Россия тарихы историографиясенә, дәүләт һәм җирле үзидарә тарихлары, Россиядә реформалар һәм революцияләр мәсьәләләренә карый. 20 йөз башы Идел буе, ш.и. Казан губернасы, аграр төзелеш һәм күпмилләтле крестьяннар тарихын, П.А.Столыпин реформаларын, ш.у. рус крәстияннәренең рухи тормышын һәм психологиясен өйрәнүгә зур өлеш кертә. К. җитәкчелегендә 2000–11 дә «Самара төбәген өйрәнү классикасы» («Классика самарского краеведения») антологиясе эшләнә һәм нәшер ителә. Пётр фәннәр академиясе һәм сәнгате, Гуманитар фәннәр академиясе, «Европа–Азия 2010» халыкара гуманитар академиясе мөхбир әгъзасы. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КАДЫ́ЙРОВ** Марат Шамил улы (3.6.1969, БАССРның Бүздәк р-ны Батырша-Кыбау а.), оркестр дирижёры, концертмейстер, симф. оркестр артисты. Казанда беренче татар хәрби дирижёры. ТРның халык артисты (2016), эчке хезмәт подполковнигы. Уфа сәнгать ин-тын (1991), Казан консерваториясен (тромбон классы) тәмамлый (1993). 1987–89 елларда Энгельс Һава һөҗүменнән саклану зенит-ракета уч-щесендә оркестр музыканты, 1991–96 да Казан югары хәрби танк команда уч-щесе оркестры концертмейстеры, бер үк вакытта, 1993–96 да, Татар филармониясе симф. оркестры артисты. 1996 дан ТР Эчке эшләр министрлыгының Мәдәни үзәге оркестры дирижёры. Татарстан, Россия шәһәрләре һәм чит илләр буйлап гастрольләргә чыга. Халыкара «Казан фанфарлары» тынлы оркестрлар фестивален оештыручы һәм аның сәнгать җитәкчесе. Оркестрның 3 дискын, ш.у. «Башкорт-татар музыкасы джаз эшкәртмәсендә» дискын чыгара. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КАЛАГА́НОВА** Нина Ивановна (11.6.1944, Удмурт АССР, Ижевск ш.), драма актрисасы, педагог. ТРның халык артисты (2014). Саратов театр уч-щесен (1969), Казан мәдәният ин-тын (1994) тәмамлый. 1970 елдан Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) актрисасы, бер үк вакытта, 1994 тән, Казан мәдәният ин-тында укыта. Театр сәхнәсендә актриса Катерина («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Таня, Нина («Июньдә хушлашу», «Бистәдә көрешү», А.Н.Вампилов), Людмила Бааль («Казан университеты. 1887 ел.», Д.Вәлиев), Хәдичә («Китәм инде», Р.Хәмид), Сычиха (шул исем. әсәр буенча, Н.Глазова), Валентина («Иртәнге күктә йолдызлар», А.Галин), Войницкая («Ваня абзый», А.П.Чехов) кебек зур әһәмияткә ия тирән мәгънәле рольләр башкара. Балалар өчен романтик рух б-н сугарылган Фея («Золушка», Е.Шварц), Әкиятче Нянюшка («Ал чәчәк», В.Пистоленко), Ташбака Тортила («Юләрләр илендә Буратино маҗаралары», А.Толстой) образларын иҗат итә. Нәфис фильмнарда төшә: «Күгәрченем» («Голубка», реж. С.Свинцов-Ольденбург), «Хәлимә» (реж. Ю.Захарова) һ.б. «Намус һәм тугрылык. Фидакарь хезмәт өчен» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге лауреаты. ТР Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1976). Медальләр б-н бүләкләнә.

**КАЛЕ́ГИНА** Ольга Анатольевна (1.2.1954, Сахалин өлкәсенең Долинск р-ны Сокол пос.), китапханә белгече, пед. фән. д-ры (2007), проф. (2011), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Казан мәдәният ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук китапханә белеме кафедрасында эшли; 1995–2012 дә китапханә-мәгълүмат ф-ты деканы. Хезмәтләре уку психологиясе һәм социологиясе, китапханә-мәгълүмат белеме үсеше мәсьәләләренә карый. РФнең мактаулы югары һө-

нәри белем бирү хезмәткәре (2009). Медаль б-н бүләкләнә.

**КАЛЕ́НСКАЯ** Наталья Валерьевна (10.7.1979, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2011), проф. (2014). Казан технол. ун-тын тәмамлый (2000). 2003–07 елларда шунда ук менеджмент кафедрасында укыта. 2007–12 дә Казан финас-икътисад ин-тында: маркетинг каф. доценты, проф. 2012 дән Казан ун-тының маркетинг каф. мөдире. Маркетологлар гильдиясе, РФ Сәүдә-сәнәгать палатасының экспертлар советы әгъзасы. Хезмәтләре инновацион үсеш инфраструктурасы, инновацияләр маркетингы, сату б-н идарә итү, бренд-менеджмент мәсьәләләренә карый.

**КАЛИ́НИН** Алексей Александрович (15.5.1975, Түбән Новгород өлкәсенең Кулебаки ш.), химик, химия фән. д-ры (2014), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2014). Казан ун-тын тәмамлый (1997). 2000 елдан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында: органик синтез, гетероциклик кушылмалар, функциональ материаллар лаб-яләрендә кече, фәнни, өлкән, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре гетероциклик кушылмалар химиясе, нәсызыкча-оптик хромофоралар һәм материаллар өлкәсенә карый. Дәүләт бүләге яңа буын дару чаралары нигезен — макроциклик кушылмаларның яңа классларын синтезлау методологиясен булдырган өчен бирелә.

**КАМАЛИ́ЕВ** Илфат Дамир улы (6.1.1973, Биектау р-ны Дөбъяз а.), драма актёры, режиссёр, сценарист. ТРның халык артисты (2019). Казан театр уч-щесен (1996), Мәскәүдә Б.Щукин исем. югары театр уч-щесен (2001) тәмамлый. Казан татар яшь тамашачылар театрында эшли (1994 елдан). Театр сәхнәсендә актёр психол. тирәнлек б-н сугарылган тормышчан драматик һәм кабатланмас комик образлар иҗат итә: Фердинанд («Мәкер һәм мәхәббәт», Ф.Шиллер), Альфред, Хәмит, Исмәгыйль («Кырларым-тугайларым», «Нигез ташлары», «Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин), Асан («Оят төне», Б.Мукаев), Ибраһим («Тайгак кичү», И.Сәлахов), Галимҗан, Галимҗанның дусты, Кәрим бай; Шаһиморат («Башмагым»; «Кыю кызлар», Т.Гыйззәт), Кирам («Кичер мине, әнкәй», Р.Батулла), Сибгат, Исмәгыйль («Галиябану», М.Фәйзи), Тимерташ («Ничек миллионер булырга?», М.Гыйләҗев), Петруччо («Тискәрегә авызлык», У.Шекспир) һ.б. К. балалар өчен Шүрәле («Тозакка төшкән аучы», Н.Дәүли), Төлке, Куян, Аю («Керпе малае дуслар эзли», «Бүре һәм Кәҗә», Р.Корбан), Кыш бабай («Кышкы экият», Ш.Фәрхетдинов) кебек үзенчәлекле әкияти образлар тудыра. Режиссёр буларак, «Ут чәчәге» (З.Хөснияр) спектаклен сәхнәгә куя. «Тутык кыңгырау», «Корыч», «Егет сүзе бер була» фильмнарын төшерә. ТР Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (2007).

**КАНТЮКО́В** Рафаэль Рәфкать улы (24.8.1975, БАССРның Салават ш.), инженер, техник фән. канд. (2010), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Яңа Уренгой газ сәнәгате техникумын (1994), Әлмәт нефть ин-тын (2003) тәмамлый. 1994–2004 елларда механика-төзекләндерү оешмасында төзекләндерүче слесарь, «Ямбурггаздобыча» ҖЧҖнең геол., чыганакларны эшкәртү һәм лицензияләү идарәсе геол. хезмәте скважиналарын тикшерүче оператор; 2004–2010 да «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖдә магистраль газүткәргечләрне һәм аларның объектларын файдалану буенча бүлек, идарә башлыгы, 2014 тән баш инженер урынбасары. Дәүләт бүләге табигый энергиянең ясалма чыганагын булдыру б-н Татарстан Респ-касының энергия иминлеген күтәрүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 4 патенты бар.

**КАРА́СИК** Андрей Анатольевич (30.9.1963, Казан), химик, химия фән. д-ры (2003), проф. (2013), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2014). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2014). Казан ун-тын тәмамлый (1986). 1986 елдан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында: стажер-тикшеренүче, инженер, кече фәнни хезмәткәр, фәнни хезмәткәр, өлкән, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, фәнни эшләр буенча директор урынбасары, беренче урынбасары, җитәкче (2017 дән). Фәнни эшчәнлегенең төп юнәлешләре фосфорның циклик һәм макроциклик химиясе үсеше б-н бәйле. К. дөньяда беренчеләрдән булып составларында 5 нче төркем элементлары (N һәм P) булган макрогетероциклларның ковалент үзтупланышы концепциясен эшли. Концепция N һәм P кергән макроциклларның яңа буынын — корандлар, циклофаннар һәм криптандлар — принципиаль яңа супрамолекуляр структуралар һәм координацион кушылмалар булдыруда уникаль төзелеш блокларын эшләүгә нигез итеп алына. К. тарафыннан яңа түбән энергетикалы процессларның, ш.и. макроциклик аминометилфосфиннар стереоизомерларының үзара әверелешенең кинетик һәм термодинамик параметрлары, алар эчендә эндоциклик кисәкчекләрнең молекуляр алмашуы, ш.у. N, P кергән гетероциклларның тараю һәм киңәю реакцияләре билгеләнә. Дәүләт бүләге «Макроциклик кушылмаларның яңа класслары — дару чараларының яңа буыны нигезен синтезлау методологиясен булдыру» хезмәте өчен бирелә. РФАнең А.Н.Несмеянов исем. бүләге лауреаты (2015). Россиянең Д.И.Менделеев исем. химия җәмгыяте әгъзасы.

**КАРПЕ́НКО** Луиза Гайнетдин кызы (25.8.1962, Минзәлә ш.), анестезиолог, мед. фән. канд. (1999), ТРның, РФнең атказ. табибе (2001, 2008), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003), РФ Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге бүләге лауреаты (2009). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1985). 1986 елдан Респ-ка онкология клиник диспансерында табиб-анестезиолог, 1999–2017 дә дәвалау эшләре буенча баш табиб урынбасары, бер үк вакытта, 2006 дан, Казан мед. академиясенең хирургия, онкология һәм паллиатив мед. кафедрасында, 2011 дән доцент. 2017 дән Казан мед. академиясенең дәвалау эшләре һәм клиник базалар б-н элемтә буенча баш табиб урынбасары. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлеше яман шешләрне дарулар б-н дәвалауга карый. Уку-укыту ярдәмлекләре авторы. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында онкология хезмәте белән идарә итүне оптимальләштерү һәм яман шешле авыруларга ярдәм күрсәтүне яхшырту һәм социаль-икътисади чыгымнарны киметү максатыннан яңа оештыру технологияләре куллану» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Россия онкологлар ассоциациясе, ТР мед. хезмәткәрләре ассоциациясе әгъзасы. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КАЮ́МОВ** Айдар Тәлгать улы (28.9.1963, Алабуга р-ны Песәй а.), тарихчы, философ, филос. фән. д-ры (2007), проф. (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1985). 1989–91 елларда Алабуга пед. ин-тында. 1991 дән Чаллы пед. ин-тында (2011 дән Чаллы социаль-пед. технологияләр һәм ресурслар ин-ты): тарих һәм социаль-гуманитар дисциплиналар каф. мөдире (1996 дан), 2006–07 дә проректор. Хезмәтләре тарих, филос., информацион җәмгыять шартларында мәгариф һәм социомәдәни үсеш мәсьәләләренә карый.

**КАЮ́МОВ** Рәфыйк Рәвгать улы (2.8.1961, Чирмешән р-ны Кара Чишмә а.), драма актёры, сценарист, режиссёр. ТРның халык артисты (2018). Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тын тәмамлый (1998). Актёрның сәхнә эшчәнлеге 1985 елда Чаллы «Энергетик» мәдәният сараендагы халык театрында «Сафура бураннары» (Ю.Әминев) спектаклендәге Флорид образы б-н башланып китә. 1991 дән Чаллы татар драма театрында эшли. Проф. сәхнә эшчәнлеге аңа танылу китергән Сәет («Гашыйклар тавы», И.Юзеев), Зәфәр («Җәйге кырау», Аманулла) кебек баш рольләрдә уйнаудан башлана. Иҗатының югары ноктасын билгеләүче Мирвәли («Өч аршын җир», А.Гыйләҗев), тирән драматизм б-н сугарылган Рыскул («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Сәгыйдулла («Язлар моңы», Ә.Гаффар), Хаммат («Изге имән шаһит», Р.Ямалиева) образлары аерым игътибарга лаек. Газап һәм әрнү, нәфрәт һәм куркy, горурлык хисләре б-н аерылып торган Эзоп («Кол», Г.Фигейредо) актёрның зур иҗат казанышы була. К. трагик һәм драматик образлар б-н рәттән Шәехморза («Американ», К.Тинчурин), Василий Дмитриевич («Банкрот», Г.Камал), Иршат («Без бит авыл малае!», Т.Миңнуллин), Закирҗан («Аты барның — дәрте бар»), Мирвәли («Мөгезле Мәүлихан», Д.Салихов), Комиссар («Саран», Ж.Б.Мольер), Жевакин, Подколесин («Өйләнү», Н.В.Гоголь) кебек комик образлар тудыру остасы буларак та таныла. ТР Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (2005). Д.Сираҗиев исем. театраль бүләк лауреаты (2017).

**КАЮ́МОВ** Рубин Расих улы (29.12.1980, Мөслим р-ны Михайловка а.), галим зоотехник, биол. фән. канд. (2008), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013). Казан вет. медицинасы академиясен тәмамлаганнан соң (2003), шунда ук механизация кафедрасында эшли. Дәү-

ләт бүләге ТРда сөт терлекчелеге тармагы нәтиҗәлелеген күтәрү өчен инновацион технологияләр эшләүдә һәм аларны гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**КАЮ́МОВА** Диана Фердинанд кызы (30.05.1976, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2009), проф. (2012). Казан пед. ун-тын тәмамлаганнан соң (1998), кызлар гимназиясендә укыта (1993–2002), Казан ун-тында эшли (2002 елдан): чит телләр укыту теориясе һәм методикасы каф. профессоры. Хезмәтләре чагыштырма-тарихи тел белеменә, типология, когнитив, фразеологик тикшеренүләргә карый. Инглиз телен укыту буенча уку-укыту–методик ярдәмлекләр авторы.

**КӘБИ́РОВА** Айсылу Шәрипҗан кызы (1.3.1966, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2013). Казан ун-тын тәмамлый (1988). 1991–96 елларда Казан пед. ун-тының Ватан тарихы кафедрасында. 1996 дан ТР ФА Тел, әдәбият һәм тарих ин-тының тарих бүлегендә, 1997 дән ТР ФА Тарих ин-тының яңа һәм иң яңа тарих бүлегендә өлкән, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре Татарстанның Бөек Ватан сугыш елларындагы тарихы, Татарстан историографиясе мәсьәләләренә карый.

**КӘЛИМУ́ЛЛИНА** Эльмира Рамил кызы (25.1.1988, Түбән Кама ш.), җырчы. ТРның атказ. артисты (2012). Казан ун-тын, Казан консерваториясен тәмамлый (2012). Халыкара, бөтенроссия, респ-ка конкурсларында катнаша. «Голос» телевизион шоу җиңүчесе (Мәскәү, 2012; 2 нче урын). Репертуарын рус, татар һәм чит ил җырлары тәшкил итә («Колыбельная», «Что потом?», «Будда», «Төнге учак», «Умырзая», «Көтәм сине», «Мин сине Ходайдан сорадым», «Cancao do mar» һ.б.). «Алтын Казан» (Э.Низамов) милли рок-операсында, «Ак бүре» (З.Рәүпова), «Өч апельсинга мәхәббәт» («Любовь к трём апельсинам», С.Прокофьев) операларында вокаль партияләр башкара. Студентларның XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасы илчесе (2013). Россия шәһәрләре буйлап һәм чит илләрдә концерт номерлары б-н гастрольләрдә йөри.

**КӘРИ́МОВ** Тәүфикъ Әкрам улы (1.2.1958, Казакъстан ССР, Гурьев өлкәсенең Гурьев ш.), тарихчы, хакимият һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы. Гурьев пед. ин-тын (1979), Алма-Ата сәясәт һәм идарә ин-тын (1991), Атырау нефть һәм газ ин-тын (1995) тәмамлый. 1979–84 елларда комсомолның Гурьев өлкә ком-ты референты, инструкторы, кадрлар секторы һәм бүлеге мөдире. 1985–89 да Казакъстан КПнең Гурьев шәһәр ком-ты инструкторы, оештыру бүлеге мөдире урынбасары. 1991–92 дә «Кантар» совет-герман пр-тиесендә әйдәп баручы белгеч. 1992–94 тә «Внешинвест» компаниясе (Атырау ш.) эксперты. 1994–2001 дә Атырау өлкәсе хакимият аппараты җитәкчесе, хакимият башлыгы урынбасары, 2002–03 тә Мәдәният һәм иҗтимагый бердәмлек министрлыгының Атырау өлкә мәгълүмат идарәсе башлыгы. 2004–07 дә Казакъстан Респ-касы Президенты администрациясенең дәүләт контроле һәм оештыру эшләре бүлеге баш инспекторы (Астана). 2007–09 да «Каспий» социаль-эшмәкәрлек корпорациясе милли компаниясе» АҖ идарәсе рәисенең 1 нче урынбасары (Актау ш.). 2009–14 тә «Нур Отан» Халык демократик партиясе Үзәк аппаратының Партия контроле ком-ты инспекторы. 2014 тән «Госэкспертиза» дәүләт пр-тиесе үзәк аппараты җитәкчесе (Астана). Бер үк вакытта, 2003–07 дә, Атырау өлкәсенең «Татулык» татар-башкорт милли-мәдәни үзәге рәисе, 2007–13 тә Казакъстан Респ-касы татар һәм башкорт милли-мәдәни үзәкләре ассоциациясе президенты. Татарстан Респ-касы (2006), Казакъстан Респ-касы (2008), Россия Федерациясе (2014) Язучылар берлекләре әгъзасы. Казакъстан халыклары ассамблеясы әгъзасы (2007–13). Казакъстан Татар һәм башкорт конгрессы рәисе (2017 дән). Фәнни хезмәтләре һәм язмалары татар халкы һәм Казакъстандагы татар диаспорасы тарихына карый. Тарихи-фәлсәфи, сюрреалистик эссе һәм шигырьләр авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КӘРИ́МОВА** Руфия Габделхәй кызы (29.11.1977, Казан), вет. физиологы, биол. фән. д-ры (2011). Казан вет. медицинасы академиясен тәмамлаганнан соң (1999), шунда ук физиол. кафедрасында эшли, доцент (2003). Хезмәтләре терлекләрнең иммун системасын, матдәләр алмашын стимуллаштыру һәм кардиотроп тәэсир итүче препаратлар (азот оксиды доноры) эшләүгә карый.

**КИРИ́ЛОВА** Галия Илдус кызы (11.4.1956, Ростов-Дон ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2002), проф. (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук эшли, 1992 елдан гамәли матем. кафедрасында. Бер үк вакытта, 1992 дән, РМАның Һөнәри белем бирү пед. һәм психол. ин-тында, 1998–2004 тә гыйльми секретарь, 2004 тән һөнәри белем бирүне мәгълүматлаштыру лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре һөнәри белем бирүдә мәгълүматлаштыру, мәгълүмати-интеллектуаль үсеш тәэмин итү мәсьәләләренә карый. РФ Хөкүмәтенең белем бирү өлкәсендәге бүләге лауреаты (2005).

**КИРПИ́ЧНИКОВ** Александр Петрович (2.10.1954, Казан – 23.11.2019, шунда ук), физик, физика-матем. фән. д-ры (2003), проф. (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), СССР ФАнең Космик тикшеренүләр ин-тында (Мәскәү) эшли; 1985 елдан Казан технол. ун-тында, 2005 тән мәгълүмати ресурслар б-н идарә итү һәм интеллектуаль системалар каф. мөдире. Хезмәтләре югары һәм түбән температуралы плазмадагы процессларны матем. модельләштерү, массакүләм хезмәт күрсәтүнең гамәли теориясе, мәгълүматны кодлаштыру теориясе өлкәсенә карый. Югары ешлыклы түбән температуралы плазманы диагностикалау өчен комплекслы контакт алымын эшли. Коаксиаль бушану күренешен ача, югары ешлыклы индукцион бушануда нуль дәрәҗәсендәге буй тизлекле өслек барлыгын ачыклый. Азаккы озынлыкның югары ешлыклы индукцион бушануының гоумиләштерелгән Томсон моделен төзи.

**КЛЁМИН** Андрей Владимирович (28.7.1961, Казан), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2005), проф. (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1987). 1987–2003 елларда Швейцария (Фрибург, Лозанна), Германия (Лейпциг, Галле, Гейдельберг), Бельгия (Левен, Гент) ун-тларында Европа берлеге хокукы мәсьәләләре буенча фәнни тикшеренү эшләре б-н шөгыльләнә. Бер үк вакытта, 1992 дә, Вена шәһәрендә Австрия сәүдә компаниясе офисы идарәчесе; 1993–2004 тә ТР ФАнең Социаль-икътисади һәм хокукый фәннәр ин-тында (фәнни хезмәткәр, өлкән фәнни хезмәткәр, хокук бүлеге мөдире); 1999–2000 дә ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте ин-тының хокук, тарих һәм политология каф. мөдире, 2004–06 да Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында Европа хокукы каф. мөдире (Казан). 2006 дан Казан инновацион ун-тының халыкара һәм Европа хокукы каф. мөдире. Хезмәтләре Европа берлеге хокукы мәсьәләләренә карый.

**КО́ВРИКОВ** Георгий Михайлович (26.8.1963, Ростов өлкәсенең Аксай ш.), җырчы (тенор), ТРның халык артисты (2003). Саратов консерваториясен (А.Алексашкин, Е.Лудер класслары) тәмамлый (1993). 1991–93 елларда — Саратов опера һәм балет театры, 1993 тән Татар опера һәм балет театры солисты. Театр труппасы б-н гастрольләрдә була, ш.и. халыкара уртак проектлар буенча куелган спектакльләрдә катнаша. Төп партияләре: Тамино («Тылсымлы флейта», В.А.Моцарт), Альмавива («Севилья чәчтарашы, Дж. Россини), Герцог, Альфред, Радамес («Риголетто», «Травиата», «Аида», Дж. Верди), Рудольф («Богема», Дж. Пуччини), Ленский («Евгений Онегин», П.Чайковский). Россиядә һәм чит илләрдә концерт программалары б-н чыгышлар ясый.

**КО́ГАН** Юрий Исаакович (20.2.1954, Казан), оркестр солисты, дирижёр, муз.-җәмәгать эшлеклесе, педагог. ТРның халык артисты (2014). Казан музыка уч-щесен (1974), Казан консерваториясен (1982) тәмамлый. Казан танк уч-щесе (1969–76, 1991–99), Казан Суворов уч-щесе (1977–79), Казан шәһәр киночелтәре (1980–85), радио һәм телевидение оркестрлары артисты; төрле елларда Казан музыка уч-щесендә, Казан консерваториясе каршындагы урта махсус музыка мәктәбендә, Казан консерваториясендә, Казан пед. ун-тында, Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында (хәзер Казан мәдәният ин-ты) укыта. 2000 елдан Казан шәһәр «Фантазия» джаз-оркестрының сәнгать җитәкчесе. Тынлы музыка уен кораллары, эстрада-симф., джаз оркестрлары, саксофон һәм фортепиано, ш.у. саксофоннар ансамбле өчен аранжировка һәм инструментовка өлкәсендә актив эшчәнлек алып бара. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КОГО́ГИН** Сергей Анатольевич (16.11.1957, Яшел Үзән р-ны Зур Ключи а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, җитештерүне оештыручы, икътисад фән. канд. (2001), ТРның атказ. машина төзүчесе (2001), РФнең атказ. транспорт хезмәткәре (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1982). 1982–85 елларда Яшел Үзән «Эра» пр-тиесендә инженер. 1985–94 тә Яшел Үзән машиналар төзү з-дында: баш инженер (1986 га кадәр), 1986–87 дә бюро башлыгы, 1987–89 да баш механик урынбасары, 1989–90 да профком рәисе, 1990 нан директор. 1994–99 да Яшел Үзән р-ны һәм Яшел Үзән шәһәре хакимияте башлыгы. Бер үк вакытта, 1995–99 да, Яшел Үзән берләштерелгән халык депутатлары Советы рәисе. 1999–2002 дә ТР Премьер-министры урынбасары – ТР икътисад һәм сәнәгать министры. 2002 дән «КАМАЗ» гаммәви АҖ ген. директоры, бер үк вакытта, 2006 дан, «Россия автомобильләр җитештерү берләшмәсе» коммерциячел булмаган партнёрлыгы б-н аның советы рәисе сыйфатында җитәкчелек итә. Хезмәтләре икътисад, индикатив планлаштыру мәсьәләләренә карый. 1995–99 да ТР халык депутаты, 2004–09 да ТР Дәүләт Советы депутаты. «АВТОВАЗ» ААҖ Директорлар советы әгъзасы (2009). Фән һәм техника өлкәсендә РФ Хөкүмәте (2009), Россия бизнес һәм эшмәкәрлек академиясенең «Дарин» бизнес-репутация милли (2004) бүләкләре лауреаты. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен», Дуслык, Почёт орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**КОЛЕТВИ́НОВА** Наталья Дмитриевна (25.4.1948), педагог, пед. фән. д-ры (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1974), Казан ун-тының Психол. һәм мәгариф ин-тында эшли, мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү каф. профессоры. Хезмәтләре башлангыч белем бирү белгечләре әзерләү мәсьәләләренә карый.

**КОЛПАКО́ВА** Галина Васильевна (3.1.1950, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2005), Горький чит телләр пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), шунда ук эшли. 1986–88 елларда инженер, хезмәтне фәнни оештыру бюросы һәм Казан исәпләү техникасы һәм информатика фәнни-җитештерү берләшмәсенең фәнни уку-укыту үзәге идарәсе башлыгы. 1988 елдан Казан ун-тында: доцент, немец һәм француз телләре каф. мөдире вазифаларын башкара (1988–97). Хезмәтләре немец теле лексикологиясе һәм стилистикасына, немец һәм рус телләренең контрастив синонимиясе, семантика, когнитив лингвистика мәсьәләләренә карый.

**КОЛПАКО́ВА** Людмила Михайловна (29.7.1950, Сахалин өлкәсенең Поронайск р-ны Леонидово пос.), психолог, психол. фән. д-ры (2012). Казан мәдәният ин-тын (1974), Казан финанс-икътисад ин-тын (1984), Казан ун-тын (1991) тәмамлый. 1975 елдан Урицкий исем. мәдәният сараенда инструктор, 1980 нән Казан финанс-икътисад ин-тының хезмәт икътисады кафедрасында лаборант, 1986 дан ТАССР Сәүдә министрлыгы каршындагы Казан укыту курслары комб-тында, 1991 дән Казанның 9 нчы мәктәбендә психолог. 1998 дән Казан мед. ун-тының мед. һәм гомуми психол. кафедрасында, 2006 дан Социаль белем бирү академиясендә гомуми психол. каф. мөдире, 2012 дән Россия Мәгариф академиясенең Һөнәри белем бирү педагогикасы һәм психологиясе ин-тында психол. лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре шәхесара мөнәсәбәтләр формалашу механизмнарын, катлаулы ситуацияләрдә яраклашу мөмкинлекләрен ачыклауга һ.б.га карый.

**КО́НЮХОВ** Геннадий Владимирович (8.10.1948, Орёл өлкәсенең Залегощь р-ны Семеново а.), радиобиолог, биол. фән. д-ры (2000), проф. (2005). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1972). 1985 елдан Хайваннарның токсикологик, радиацион һәм биол. куркынычсызлыгы федераль үзәгендә радиобиол. лаб-ясе, 1993 тән радиобиол. бүлеге мөдире. Тикшеренүләренең гамәли әһәмияте а.х. терлекләре организмына радиацион йогынтыны киметүгә карый. Ашыгыч диагноз кую ысулларын эшләү һәм гамәлгә кертү; а.х. терлекләренең радиацион һәм катнаш зыян күрүе очракларында авыруны кисәтү һәм дәвалауның махсус ысулларын эшләү; гадәттән тыш хәлләр очрагында итне саклау ысулларын булдыруга багышланган хезмәтләре өчен ВДНХның алтын медаленә, Бөтенроссия күргәзмәләр үзәгенең бронза һәм көмеш медальләренә, ТР МКның 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә дипломнарына лаек була. ТР ФА тарафыннан «Елның иң яхшы галиме» дип танылa (2009). Вет. өлкәсендә гамәлгә кертелгән 21 уйлап табуга патенты бар, аларның дүртесе ТР буенча иң яхшы уйлап табу үрнәге дип табыла (2002, 2003, 2005, 2014). Медальләр б-н бүләкләнә. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша (1986–88).

**КОРАБЛЁВ** Алексей Михайлович (21.3.1979, Чистай р-ны Галактионово а.), РФ Герое (28.6.2000), гв. рядовое. 1995–98 елларда Чистай сәгать з-дында слесарь булып эшли. 1998 дән РФ Кораллы Көчләрендә, 160 нчы гв. танк полкында хезмәт итә. Икенче чечен кампаниясе вакытында (1999–2009) Бамут, Шали, Урус-Мартан авыллары алу буенча оештырылган сугышчан операцияләрдә катнаша. Чечен Респ-касының Шали р-ны Дуба-Юрт авылы тирәсендә батырлык күрсәтә. 2000 нең 15 гыйнварында Россия гаскәрләренең разведка төркеме төп көчләрдән аерыла һәм каршы як урнашкан биеклектә камалышта кала. 36 солдат полк артиллериясе ярдәмендә берничә сәгать 170 кешелек хәрби төзелмәгә каршы тигез булмаган сугыш алып бара. 5 кеше генә исән кала. К. берүзе иптәшләренең чигенүен тәэмин итә, авыр яраланган солдатны коткара. 2000 нән запаста. Чистай шәһәрендә яши, Чистай р-ны әфган һәм чечен сугышлары ветераннарының «Патриот» иҗтимагый оешмасы президенты.

**КОРБАНГАЛИ́ЕВ** Артур Ришат улы (14.12.1980, Уфа ш. — 9.9.1999, Дагстан Респ-касы Новолакское р-ны; Чиләбе өлкәсенең Усть-Катав шәһәрендә җирләнә), РФ Герое (30.12.1999, үлгәннән соң), гв. сержанты. 1998 дән РФ Кораллы Көчләрендә, 119 нчы парашютчы десант гв. полкы 4 нче парашютчы десант ротасының парашютчы десант взводы командиры урынбасары. Икенче чечен кампаниясе вакытында (1999–2009) 1999 ның сентябрендә Дагстан Респ-касының Новолакское районында батырлык күрсәтә: хәрби төзелмәләрнең ныгытылган позицияләрен штурмлаганда, рота көчле миномёт утына тотыла, командир яралангач, К. аның вазифасын башкара, яраланган иптәшләрен коткарганда һәлак була. Медаль б-н бүләкләнә. Уфада 14 нче йортның һәм Усть-Катавтагы мәктәпнең фасадларына Геройга мемориаль такталар куела.

**КОЧУ́РОВ** Шәйхелислам Габделвәһап улы (30.11.1850, Чиләбе өлкәсенең Варна р-ны Варна а. – гыйнвар,1918, Оренбург ш.), генерал-лейтенант (1910). Оренбург казак юнкерлар уч-щесен тәмамлаганнан соң (1870), Оренбург казак гаскәрләрендә хезмәт итә, 4 нче казак полкы командиры (1900–05). 1905 елдан Төркестан казак дивизиясенең 1 нче, 1906 дан 2 нче бригадасы командиры. 1910 нан отставкада. 3 нче дәрәҗә Изге Станислав, 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче дәрәҗә Изге Станислав, 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 3 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

**КРАВЦО́В** Яков Исаакович (27.2.1934, Винница өлкәсенең Ильинцы ш. — 11.9.2017, Казан), техник, техник фән. д-ры (1998). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1959). 1959–72 елларда «Союз» тәҗрибә КБда әйдәп баручы инженер — исәпләүче конструктор, 1972–87 дә Татарстан нефть машиналары төзү ин-тында (ТатНИИнефтемаш) фәнни-тикшеренү эшләре лаб-ясе мөдире, 1987–2017 дә РФА КГҮнең Энергетика бүлегендә (хәзер Энергетика һәм перспектив технологияләр ин-ты) лаб. мөдире, директор урынбасары, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. К. фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре — ракета двигательләренең яңа классын булдыру һәм гамәлгә кертү, авиация һәм ракета двигательләре җирлегендә һәм аларның эш принципларына нигезләнеп, энергетика җайланмалары эшләү, югары дәрәҗәдә үзле нефть һәм табигый битум энергетика комплексларын, аларны чыгару алымнарын һәм чараларын камилләштерү, авыр чыгарылучы нефть запасларын чыгару процессын камилләштерү һәм продуктив катламнарга бердәм тәэсир итүнең техник чараларын булдыру. «Татарстан Республикасының иң яхшы 50 инновация идеяләре» конкурсында җиңүче. Уйлап табуга 50 дән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КРА́МИН** Тимур Владимирович (19.6.1970, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры

(2007), проф. (2009). Казан ун-тын (1992), Боулдер ун-тын (АКШ, Колорадо штаты, 1999), Казан технол. ун-тын (2007) тәмамлый. 1996 елдан Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында эшли, финанс менеджменты каф. мөдире (1999 дан); Социаль-икътисади үсеш проблемалары ин-ты директоры (2007 дән). Хезмәтләре Россия пр-тиеләренең финанс ныклыгы, институциональ икътисадта компанияләрне бәяләү б-н идарә итү мәсьәләләренә карый. Беренче мәртәбә чиктәш элементлар алымы б-н пластиналарның киеренке-деформацияле халәтен һәм катлаулы формалы сөзәк тышчаларны исәпләү өчен тигезләмәләр чыгара. Россиядә керемгә карап алына торган салымга кредит программасын һәм Россия төбәкләренең (ТР мисалында) инвестицион кызыксындыручанлыгы б-н идарә итү механизмын тәкъдим итә.

**КРЫЛО́В** Вячеслав Николаевич (6.12.1961, Ульянов өлкәсенең Карсун пос.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2008), проф. (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1986). 1989 елдан рус һәм чит ил әдәбияты кафедрасында (хәзер Филология һәм мәдәниятара багланышлар ин-ты). Хезмәтләре 19 йөз ахыры – 20 йөз башы рус әдәбияты тарихы, әдәби тәнкыйть теориясе һәм тарихы, жанрлар, поэтика мәсьәләләренә карый.

**КУЛЬКО́ВА** Мария Александровна (17.10.1980, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2011), проф. (2018). Казан пед. ун-тын тәмамлый (2002). 2002–06 елларда — Татар-Америка региональ ин-тының лингвистика һәм мәдәниятара багланышлар, 2006–11 дә — Икътисад, идарә һәм хокук ин-тының тәрҗемә һәм тәрҗемә белеме, 2010–11 дә Татар гуманитар-пед. ун-тының рус теле һәм укыту методикасы кафедралары доценты. 2011–13 тә Казан ун-тының немец филологиясе каф. мөдире, 2013 тән герман филологиясе каф. профессоры. Россия герман филологиясе белгечләре берлеге, EUROPHRAS халыкара фразеологлар ассоциациясе әгъзасы. Хезмәтләре когнитив лингвистика, прагмалингвистика, мәдәниятара багланышлар, мәгариф, фән һәм мәдәният өлкәсендә Россия-Германия диалогы мәсьәләләренә карый.

**КУРБА́ТОВА** Надежда Васильевна (3.4.1952, Казан), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли. Хезмәтләре нефть чыгару районнарында төче су чыганаклары торышын контрольдә тоту өчен флуоресцент индикаторлар алымын куллануга карый. Дәүләт бүләге гидрогеол. өлкәсендә һәм Татарстан нефть чыганакларын эшкәртүне контрольдә тоту максатында аппаратура-методик индикаторлар комплексын эшләүдә һәм аны гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**КУ́РКИН** Михаил Иванович (13.8.1938, Мәскәү), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1980), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). Урал ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), РФАнең Урал бүлегендә (Екатеринбург ш.) Металлар физикасы ин-тында эшли: әйдәп баручы хезмәткәр (1986 елдан), теоретик физика бүлеге мөдире (1988 дән), шул исем. лаб. мөдире (1996 дан), баш фәнни хезмәткәр (2005 тән). Хезмәтләре каты җисемнәр физикасына, магнитлы күренешләр физикасына карый. Фемтосекундлы лазер импульслары өчен бер импульслы элементар кисәкчекләрнең хәрәкәт микъдары кайтавазының һәм Фарадей кире эффектының эффектлылыгын фаразлый. Дәүләт бүләге кристалларда акустик дулкыннарның квантлы система б-н үзара тәэсир итү эффектларын өйрәнүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**КУСЮ́МОВ** Александр Николаевич (16.8.1958, Әстерхан ш.), математик һәм механик, физика-матем. фән. д-ры (2004). 1981 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, аэрогидродинамика каф. профессоры (2005–11), санлы аэродинамик модельләштерү һәм эксперимент лаб-ясе мөдире (2011 дән). Хезмәтләре дифференциаль тигезләмәләрне тикшерү алымнарына карый. Төркем анализына һәм аерым чыгарылмаларда дифференциаль тигезләмәләрне саклау законнарын төзүгә дифференциаль-геом. якын килү алымын үстерә. Э.Нётерның нәвариацияле тигезләмәләр системасы очрагында симметрияләр б-н Ли төркемнәре арасындагы бәйләнешне билгеләүче теоремасын гомумиләштерә. Вертолёт компоновкалары һәм аларның элементларын ягалап агуның санлы модельләштерүен эшли.

**КЫЯ́МОВ** Илдар Әгъләмәтдин улы (11.02.1971, Чирмешән р-ны Кара Чишмә а.), журналист, конферансье, телевидениедә алып баручы, җырчы. Казан ун-тын (1993), Казан консерваториясен (1999) тәмамлый. 1997 елдан «Казан» милли мәдәният үзәгендә конферансье, сценарист. 2003 тән — «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясендә «Хәерле иртә, Татарстан!» (хәзер «Манзара»), бер үк вакытта, 2012 дән, «ТНВ-Планета» каналында «Татарлар» тапшыруларын алып бара. К. — «Моңлы Саз, моңлы гомер» (2003), «Мин сәхнәдә — рухани» (2017) басмаларының автор-төзүчесе, «Чирмешән районы: еллар һәм кешеләр» (2007) җыентыгын төзүчеләрнең берсе һәм мөхәррире, «Кара Чишмә карьясе» (2017) китабы авторы. Гомуми белем бирүче уку-укыту оешмалары өчен рус теленнән дәреслекләр тәрҗемә итә. Алып баручы һәм җырчы буларак концертларда катнаша. «Җырларым» фильм-концерты бар. Нәфис фильмнарда төшә. «Бәллүр каләм – Хрустальное перо» конкурсының «Журналистикада билгеле исем» номинациясе лауреаты (2011). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЛАВРО́В** Николай Иванович (31.7.1958, Яшел Үзән р-ны Васильево штп), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), Павлоград химия з-дында (Украина ССР) механика-энергетика хезмәте башлыгы булып эшли. 1987–2008 елларда «Кварт» АҖдә: механик (1990 нан), цех башлыгы (1993 тән). 2008 дән «ХайТек Консалтинг» ҖЧҖдә (Казан) производство башлыгы. Дәүләт бүләге яңа буын композицион материаллар — ТРда җитештерелгән эре тоннажлы полимерлар нигезендә динамик термоэластопластлар эшләүдә һәм җитештерүне оештыруда катнашканы өчен бирелә.

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Далис Гариф улы (12.3.1952, Буа р-ны Яңа Чәчкап а.), вет. паразитологы, вет. фән. д-ры (2010). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), Удмурт АССРның Шаркан р-ны «Суроновский» с-зында баш вет. табибе булып эшли. 1977–87 елларда Бөтенсоюз вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан). 1987–90 да респ-ка вет. станциясендә әйдәп баручы вет. табибе, 1990–99 да Биектау р-ның баш вет. табибе урынбасары. 1999 дан Казан вет. медицинасы академиясенең паразитология кафедрасында, 2010 нан патологик анатомия каф. доценты. Хезмәтләре диагностиканың нәтиҗәле ысулларын эшләү һәм камилләштерүгә, терлекләр гельминтозлары терапиясенә һәм профилактикасына карый.

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Наил Гариф улы (29.1.1923, Казан — 11.11.1971, шунда ук), геолог, геол.-минер. фән. канд. (1956), Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1948), Геолнеруд үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. Хезмәтләре тимер рудалы, апатитлы, ванадийлы, карбонатлы чимал геологиясенә карый. СССРдагы апатитлы формацияләрнең беренче картасын, апатитларның табылу урыннарын эзләү буенча методик кулланмалар төзүдә катнаша. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЛЕБЕ́ДИЧ** Сергей Петрович (4.11.1930, БАССРның Иглин р-ны Старуновка а. — 9.4.2009, Бөгелмә ш.), нефтьче, җитештерүне оештыручы, «Төньяк-көнбатыш магистраль нефть үткәргечләре» (ТКМНҮ) АҖ ген. директоры, техник фән. канд. (1979), ТАССР һәм БРның атказ. нефтьчесе (1984, 1998), РСФСРның атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (1991). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), ТКМНҮдә эшли: нефть кудыргыч станциянең, нефть үткәргечнең техник җитәкчесе, ТАССРда төзелүче үткәргеч торбалар дирекциясенең баш инженеры, ТКМНҮ идарәсенең баш инженеры, башлыгы (1980 елдан). Л. җитәкчелегендә 30 дан артык нефть кудыргыч станцияләр, гомуми озынлыгы 6 мең *км* дан арткан 10 нан артык магистраль нефть үткәргече салына; 200 мең $м^2$ дан артык мәйданда торак, күп кенә социаль-мәдәни объектлар төзелә. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы бар. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Бөгелмә шәһәренең мактаулы гражданы (1990), шәһәрдә бер урам Л. исемен йөртә; АҖ идарәсе бинасына һәм Л. яшәгән йортка мемориаль такталар куела.

**ЛЕТЯ́ЕВ** Валерий Алексеевич (30.10.1958, Волгоград өлкәсенең Волжск ш.), тарихчы, хокук белгече, тарих фән.канд. (1989), юри-

дик фән. д-ры (2002), проф. (2006). Иваново ун-тын тәмамлый (1981). 2006–09 елларда Волгоград ун-тының Волжск гуманитар ин-ты (ф-лы) хокук һәм дәүләт тарихы һәм теориясе каф. мөдире, 2009 дан Казан ун-тының Халыкара мөнәсәбәтләр ин-ты директоры урынбасары һәм профессоры. Хезмәтләре антик Рим тарихы историографиясе, Россиядә 19 гасырда – 20 гасыр башында Рим хокукы мәсьәләләренә һ.б.га карый. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2004).

**ЛИПАКО́В** Евгений Васильевич (13.4.1959, Казан — 2.7.2012, шунда ук), тарихчы, тарих фән. канд. (1990). Казан ун-тын тәмамлый (1982). 1989 елдан ТР ФА Тел, әдәбият һәм тарих ин-тының (1997 дән Тарих ин-ты) тарихи һәм мәдәни истәлекләр тупланмасы бүлеге хезмәткәре. 2003 тән ТР ФА Татар энциклопедиясе ин-тында (хәзер Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-ты), 2007 дән фән, мәгариф һәм мәдәният бүлеге мөдире. Бер үк вакытта, 1997 дән, Казан руханилар семинариясендә укыта, 2005 тән Казан епархиясенең Канунлаштыру комиссиясе рәисе. Урта гасырлардагы Казан төбәген, Татарстанның тарихи һәм мәдәни истәлекләрен өйрәнүгә зур өлеш кертә. Хезмәтләре 16–17 йөзләрдәге Казан дворяннары, Казан руханилар семинариясе тарихына, Казан архипастырьлары, некропольләре, Казан Мәрьям Ана иконасы мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**ЛИПА́ТОВ** Николай Фёдорович (22.8.1951, Казан), хәрби дирижёр, педагог, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994), ТРның халык артисты (2001), подполковник (2000). Мәскәү консерваториясен тәмамлаганнан соң (1979), Көнбатыш хәрби группаның Оштац шәһәрендәге (ГДР) 66533 нче хәрби частенда хәрби дирижёр, 1984–90 елларда Саратов югары хәрби авиация уч-щесендә оркестр башлыгы, 1990–2007 дә Чиләбе танк ин-тының Казан ф-лында оркестр башлыгы, дирижёр, ТРның баш хәрби дирижёры, 2007 дән ТРның баш хәрби дирижёры киңәшчесе. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЛОБКАРЁВ** Олег Александрович (5.1.1956, Куйбышев өлкәсенең Елховка р-ны Константиновка а.), уролог, мед. фән. д-ры (2005). Куйбышев мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), Казанда Респ-ка клиник хастаханәсендә эшли. 1996 елдан Казан мед. академиясенең урология һәм нефрология кафедрасында, каф. профессоры (2010). Хезмәтләре ир-атларда простатитларны ачыклауга, дәвалауга һәм кисәтүгә карый.

**ЛЮБЕ́ЦКИЙ** Сергей Владимирович (21.7.1967, Лениногорск ш.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1992), «Татнефть» АҖнең «Лениногорскнефть» НГДУында эшли: оператор, мастер, цех башлыгы урынбасары, бүлек башлыгы, капиталь төзекләндерү һәм скважиналар төзү буенча идарә башлыгы урынбасары (2007 елдан). Уйлап табуга 2 патенты бар. Дәүләт бүләге нефтьне промыселдан транспортлауның ышанычлылыгын арттыру буенча технол. ысуллар комплексын тикшерүдә һәм сәнәгатьтә гамәлгә ашыруда катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**МАКА́РОВА** Венера Фәйзи кызы (5.2.1968, Әгерҗе р-ны Яңа Акхуҗа а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2014), проф. (2016). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1993), Чаллы пед. ин-тында эшли. Хезмәтләре 20 йөз татар әдәбиятында сатира мәсьәләләренә, Х.Сарьян прозасының поэтикасына карый. РФнең мактаулы мәгариф хезмәткәре (2018).

**МАКСИ́МОВ** Илья Николаевич (6.8.1963, Саба р-ны Тәмте а.), педагог, рәссам, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2019). Чаллы пед. ин-тын тәмамлый (2005). 1982–96 елларда (бүленеп) Алабуга мәдәният бүлегендә, 1996–97 дә Алабуга иҗади-житештерү участогында, 1997–2000 дә Алабуга үзәк китапханә системасында рәссам; 2000–02 дә Алабуга шәһәр төзелеше архит-расы идарәсендә баш рәссам, 2002–03 тә Алабуга дәүләт музей-саклаулыгында рәссам, 2003–09 да Алабуга 1 нче балалар сәнгать мәктәбендә, 2009–14 тә Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллиятендә, 2014–17 дә Алабуга пед. ин-тында (Казан ун-ты ф-лы), 2017 дән кабат Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллиятендә («дизайн» бүлеге мөдире) укыта. М. зона, төбәкара, бөтенроссия күргәзмәләрендә, күчмә пленэрларда, Халыкара арт-симпозиумнарда актив катнаша. Рәссам ш.у. керәшен татарларның тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә зур игътибар бирә. Аның әсәрләре Кытай һәм Португалия күргәзмә залларында күрсәтелә, Волгоград, Козьмодемьянск, Алабуга музейларында, Россия, Германия, Кытайда шәхси тупланмаларда саклана. Авторлык программалары төзи һәм кайбер фәннәрнең модульле тәэмин ителешен гамәлгә ашыра. ТР Рәссамнар берлеге әгъзасы (2014).

**МАЛИВА́НОВ** Николай Николаевич (17.11.1951), педагог, пед. фән. д-ры (2004). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), шунда ук эшли, автоматика һәм электрон приборлар төзелеше ф-ты деканы (1991–99), Өзлексез белем бирү үзәге директоры (1996 дан), автоматика һәм идарә каф. профессоры (2004 тән). Хезмәтләре идарә системалары мәсьәләләренә карый.

**МАРТЫ́НОВ** Дмитрий Евгеньевич (12.3.1980, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2014). Казан ун-тын тәмамлый (2002). 2005 елдан Казан ун-тында: 2011–16 елларда Шәрекъне өйрәнү ин-тының шәрекъ тарихы һәм мәдәнияте каф. доценты, 2016 дан Халыкара мөнәсәбәтләрне өйрәнү ин-тының Алтайны һәм Кытайны өйрәнү каф. профессоры. Хезмәтләре Кытайны өйрәнү өлкәсенә карый: Кытайда җәмәгать фикере һәм утопик фикер тарихы, Кытай фәлсәфәчеләре даирәсенең (Кан Ювэй, Лян Цичао, Чжан Бинлинь) интеллектуаль мирасын өйрәнүгә һ.б.га карый. Россия интеллектуаль тарих җәмгыяте әгъзасы (2008).

**МӘКЪСУ́ТОВ** Рәхим Сәхибгали улы (1.5.1899, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Каран а. – 1.1.1950, Казан), генерал-майор (1943), Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Татарстан ҮБКның Берләштерелгән татар-башкорт хәрби мәктәбен (1925), Эшче-крәстияннәр Кызыл Армиясенең командирлар составы «Выстрел» югары укчылар мәктәбен (1938) тәмамлый. 1918–20 елларда Н.Д.Каширин җитәкчелегендәге Көньяк Урал җыелма партизаннар отряды составында акгвардиячеләргә каршы сугышчан операцияләрдә катнаша. 1922 дә басмачыларга каршы көрәшү өчен Төркестан фронтына җибәрелә. 1938 дән Ерак Көнчыгыш хәрби округында, 66 нчы укчы дивизиянең 108 нче укчы полкы командиры. 1941 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында: 58 нче укчы корпусның 42 нче механикалаштырылган бригадасы командиры (1941 нең октябре – 1942 нең декабре, полковник); 1942–45 тә 190, 192, 184, 352 нче укчы дивизияләр б-н җитәкчелек итә. 1944 тә М. җитәкчелегендәге 184 нче Кызыл байраклы Орша-Хинган укчы дивизиясе Көнчыгыш Пруссия һөҗүм операциясендә батырлык күрсәтә. 1945 нең мартыннан 352 нче Кызыл байраклы, Суворов орденлы Орша дивизиясе Көнчыгыш Пруссиядә сугышлар алып бара, Штайнайнен торак пункты тирәсендә оборона сызыгын өзә, Тройбург, Летцен шәһәрләре, Гросс-Хоппенбурх станциясе алына; сугыш хәрәкәтләрен җәелдереп, 29 мартта дивизия Фришес-Гафф култыгына чыга. 1946 дан М. отставкада, Казанда яши. Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**әл-МӘМДӘЛИ́** Бәхтияр (Бәхтияр Габделҗәлил улы Габделҗәлилов, Бәхтияр бине Габделҗәлил бине Габдулла бине Котлы әл-Юртыши) (1828, Казан губ., Казан өязе Юртыш а. — 13.11.1890, Казан губ., Казан өязе Мәмдәл а.), дин эшлеклесе, педагог. 1849–1872 елларда Царёвококшайск өязенең Күлбаш, 1872–90 да Казан өязенең Мәмдәл авылларында имам-хатип һәм мөдәррис вазифаларын башкара. Уллары Казан һәм Вятка губерналары авылларында имам-хатиплар булалар. Дини белем һәм тәрбия бирүгә багышланган китаплар авторы.

**МИНГАЛИ́ЕВ** Минневәрис Харис улы (Вәрис Гали) (16.11.1959, Мамадыш р-ны Кече Кирмән а.), журналист, язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1983). 1978–84, 1986–90 елларда Мамадыш р-ның «Коммунистик хезмәт өчен» г-тасында хәбәрче, бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип булып эшли. 1984–85 тә Мамадыш р-ны кино челтәрендә директор урынбасары һәм директор вазифаларын башкаручы. 1990–96 да Мамадыш район басмаханәсе директоры. 1996 дан Мамадыш р-ны «Нократ» г-тасында мөхәррир урынбасары, 2003 тән ген. директорның беренче урынбасары. 2008 дән «ТАТМЕДИА» АҖнең «Мамадыш-информ» ф-лы җаваплы сәркәтибе – баш мөхәррир урынбасары. «Бәхет күпере»,

«Дуслар бүләге», «Күңелле китап», «Бөркет тау», «Мамадышым — язмышым. Мамадыш — судьба моя», «Сто лет газетной строки» һ.б. китаплар авторы. ТР Язучылар берлеге һәм Мамадыш р-ны хакимиятенең Шәйхи Маннур исем. премиясе (2003), ТР Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм» бүләге (2011) лауреаты. Татарстан Респ-касы мөселманнарының Дини нәзарәте, Россия ислам университеты, Бөтендөнья татар конгрессының «Таян Аллага!» конкурсында Гран-при яулый (2014). Журналистлар (1987), ТР Язучылар (2012) берлекләре әгъзасы.

**МИНЕКӘ́ЕВ** Рогат Вәгыйзь улы (28.7.1962, Әлмәт р-ны Түбән Абдул а.), җир эшкәртү өлкәсендәге галим агроном, а.х. фән. канд. (1996). Казан а.х. ин-тын (хәзер Казан аграр ун-ты) тәмамлаганнан соң (1987), шунда ук гомуми җир эшкәртү, үсемлекләрне саклау һәм селекция кафедрасында эшли, 2009 елдан аграр ф-т деканы. Тикшеренүләре төбәкләрнең туфрак-климат шартларын исәпкә алып туфракны ноль системада (Nj-till) эшкәртүдә а.х. культураларын игүнең югары нәтиҗәле технологияләренә карый. Үсемлек мүлчәләре артуының туфрактан дым югалуны киметүгә йогынтысын өйрәнә. Медаль б-н бүләкләнә.

**МИҢЛЕБА́ЕВ** Гомәр Хазинур улы (22.10.1923, БАССРның Бәләбәй кантоны Урзайбаш а. – 19.11.1999, Краснодар краеның Геленджик ш.), очучы, майор, Сов. Союзы Герое (1945). Молотов (хәзер Пермь) очучылар хәрби мәктәбен (1942), Уфа югары партия мәктәбен (1959), Алма-Ата халык хуҗалыгы ин-тын (1965) тәмамлый. 1943 елның апреленнән Бөек Ватан сугышында: Көньяк, 4 нче Украина, 3 нче, 2 нче, 1 нче Балтыйк буе, Ленинград фронтларында, штурмовиклар эскадрильясе командиры урынбасары. 1943 нең сентябреннән 1944 нең сентябренә кадәр Ил-2 самолётында 121 сугышчан очыш ясый (шуларның 40 ында — төркем җитәкчесе). Дошманның күпсанлы тере көчләрен һәм техникасын юк итә. Запаска чыкканнан соң (1946), Казакъстан ССРдагы партия оешмаларында, 1959 дан «Туймазынефть» НГДУында (БАССР, Октябрьский ш.) эшли. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**МИҢНЕХА́НОВ** Фидаил Гыймран улы (16.8.1956, Алексеев р-ны Кыр Шонталысы а.), тарихчы, тарих фән. канд. (1986). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1982), Казан төзүче инженерлар ин-тында (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты), өлкән укытучы, доцент (1993 тән). 2011 елдан — ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-тының өлкән фәнни хезмәткәре. Фәнни тикшеренүләре милли мәгариф һәм миллият өлкәсенә, Россия һәм Татарстандагы милләтара мөнәсәбәтләргә, Татарстан Респ-касында милли телләр кулланылышын гамәлгә ашыруга, ш.у. Бөек Ватан сугышы тарихын, сугыш һәм тынычлык мәсьәләләрен өйрәнүгә карый. 1990 еллар башында респ-када беренчеләрдән булып студентларны татар телендә укытуны гамәлгә кертә, Татарстанның югары уку йортларында Россия тарихын татарча укыту өчен уку-укыту–методик ярдәмлекләр авторы.

**МИҢНУ́ЛЛИН** Җәүдәт Сәлим улы (7.10.1953, Кама Тамагы р-ны Чаллы а. – 9.10.2019, Казан), тарихчы, археограф, тарих фәннәре канд. (1988). Казан ун-тын тәмамлый (1980). 1983–89 елларда «Казан утлары» ж-лы редакциясендә эшли. 1989 дан Казан ун-тында, доцент (1996 дан). Бер үк вакытта ун-тның Н.И.Лобачевский исем. Фәнни китапханәсендә Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең шәрекъ секторы мөдире, 2000 нән баш китапханәче, 2008–11 дә директоры: 2010 нан «Җыен» фондының «Шәхесләребез» фәнни-популяр җыентыклар сериясе фәнни мөхәррире. 1975 тән археография экспедициясендә (М.Г.Госманов, Р.Ә.Шәйхиев, И.А.Гыйләҗев һ.б. б-н берлектә) катнаша, 1990 нан җитәкчесе була. Россиянең татарлар күпләп яшәгән төбәкләрендә сакланып калган кулъязма хәлендәге борыңгы төрки-татар ядкәрләрне барлау һәм өйрәнүгә зур өлеш кертә. Хезмәтләре 19 йөз ахыры – 20 йөз башы татар халкы тарихына, Шәрекъ палеографиясе, чыганакларны өйрәнү, иске татар язуы һәм текстология мәсьәләләренә, татар иҗтимагый-сәяси эшлеклеләре һәм хәйрия җәмгыятьләренә карый. РФнең мактаулы югары белем бирү хезмәткәре (2008). Медальләр б-н бүләкләнә.

**МИХЕ́ЕВ** Николай Иванович (16.5.1959, Киров өлкәсенең Советск р-ны Матушканы а.), гидродинамика һәм җылылык алмашы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1998), проф. (2011), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2009). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), «Союз» тәҗрибә КБнда (Казан) инженер-конструктор (1982–89), бригада башлыгы (1989–91), бүлек башлыгы (1991–94) булып эшли. 1994 елдан РФА КГҮнең гидродинамика һәм җылылык алмашы лаб-ясе өлкән фәнни хезмәткәре, 1998–2000 дә әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. 1999 дан Казан техник ун-тының ракета двигательләре һәм энергетика җайланмалары каф. профессоры, 2000 нән РФА КГҮнең гидродинамика һәм җылылык алмашы лаб-ясе мөдире, 2018 дән РФА КГҮнең Энергетика һәм перспектив технологияләр ин-ты җитәкчесе. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре турбулентлык, гидродинамика, җылылык алмашы, ракета двигательләре, болытларга тәэсир итү ракеталарына карый.

**МОРТА́ЗИН** Фирзәр Солтан улы (21.1.1958, Буа р-ны Кайбыч а.), композитор, җырчы. ТРның халык артисты (2018). Ленинград пед. уч-щесен (1976), Казан финанс, икътисад һәм информатика ин-тын (2009) тәмамлый. 1976–88 елларда Буа шикәр з-дында үзешчән коллективның сәнгать җитәкчесе. 1988 дән автор-башкаручы буларак проф. сәхнә эшчәнлегенә күчә. 2015 тән Буа драма театрында музыка бүлеге мөдире. Аеруча популяр җырлары: «Бер генә минутка» (Д.Камалетдинова сүзләре), «Кайтам әле балачакка» (Ф.Терегулова сүзләре), «Хуш инде» (И.Юзеев сүзләре), «Җәяүле буран» (Н.Галимов сүзләре), «Синсез дә яшәп булмый» (Л.Дәүләтова сүзләре), «Сине югалтудан куркам» (А.Сәлахова сүзләре) һ.б. Медаль б-н бүләкләнә.

**МОСТА́ФИН** Илгиз Гатаулла улы (1939, (башка чыганаклар буенча 1940) ТАССРның Тәтеш р-ны Олы Тархан а.), генерал-майор (1989). СССР Дәүләт куркынычсызлыгы ком-тының Мәскәү чик буе хезмәте уч-щесен (1964), СССР МС каршындагы Дәүләт куркынычсызлыгы ком-ты югары мәктәбен тәмамлый (1974). 1964 елдан чик буе гаскәрләре һәм дәүләт куркынычсызлыгы органнарында: өлкән оперуполномоченный, 1981 дән Урта Азия чик буе округының Махсус бүлеге башлыгы урынбасары, 1986–92 дә СССР Дәүләт куркынычсызлыгы ком-тының Ерак Көнчыгыш чик буе округы буенча Махсус бүлеге башлыгы. 1992 дән РФ Федераль куркынычсызлык хезмәте хәрби контрразведкасында, 1994–97 дә Идел буе Хәрби округы буенча Федераль куркынычсызлык хезмәте идарәсе башлыгының беренче урынбасары. 1997 дән отставкада. Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**МӨХӘММӘДИ́ЕВ** Алмаз Рәис улы (25.6.1968, Казан), тарихчы, хокук белгече, тарих фән. д-ры (2018). Казан ун-тының тарих (1992) һәм юридик (2001) ф-тларын тәмамлый. 1991 елдан ТР Дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында мөхәррир-алып баручы. 1996 дан ТР Дәүләт Советының Парламент контроле ком-ты баш белгече. 1998 дән «Дулкын ТР» телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе директоры. 2000 нән РФ Югары мәхкәмәсе каршындагы ТР Мәхкәмә департаменты идарәсе әйдәп баручы белгече; ТР Югары мәхкәмәсенең федераль дәүләт гражданлык хезмәте рәисе урынбасары, консультант. 2008 дән ТР ФА Тарих ин-тында. Хезмәтләре Идел буе Болгар дәүләтенең хокукый системасы, Татарстанның хокук саклау һәм мәхкәмәләр тарихына карый.

**МӨХӘММӘТҖА́НОВА** Лилия Хатип кызы (9.1.1973, Мамадыш р-ны Түбән Ушма а.), фольклорчы, филол. фән. д-ры (2015). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1995), 1995–96 елларда Казанда 5 нче гимназиядә укыта, 1997–2003 тә 7 нче мәктәптә директор урынбасары булып эшли. 2000 нән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер Тел, әдәбият һәм сәнгать) ин-тының фольклор бүлегендә, бер үк вакытта, 2003–04 тә, Казан пед. ун-тында, 2006–07 дә Казан пед. көллиятендә укыта. Хезмәтләре татар фольклорының эпос жанры мәсьәләләренә карый.

**МӨХӘММӘ́ТШИН** Зөфәр Гомәр улы (24.12.1960, Кама Тамагы р-ны Иске Барыш а.), әдәбият галиме, текстолог, филол. фән. канд. (1999), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан ун-тын тәмамлаганнан

соң (1984), 1984–86 елларда Иске Барыш мәктәбендә укыта, 1986–89 да Чаллы шәһәр хуҗалыгы идарәсендә эшли, 1989 дан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Н.Хисамов б-н берлектә Г.Тукайның ике томлы «Сайланма әсәрләре»нең 1 нче томын (2006), Р.Кадыйров б-н берлектә Г.Тукайның алты томлы акад. басмасының 1 нче томын (2011), Г.Исхакыйның 15 томлы «Әсәрләр» тупланмасының 11, 12, 13 томнарын төзүче. Дәүләт бүләге Г.Исхакыйның 15 томлы «Әсәрләр» басмасы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**МӨХӘММӘ́ТШИН** Игорь Тимербулат улы (15.8.1963, БАССР, Нефтекамск ш.), Россия хәрби эшлеклесе, вице-адмирал (2010). Макаров исем. Тын океан югары хәрби-диңгез училищесен (1986), Хәрби-Диңгез Флотының Югары махсус офицерлар классларын (1994), Кузнецов исем. Хәрби-Диңгез академиясен (2001), Генштаб Хәрби академиясен (2006) тәмамлый. 1994–2001 елларда Төньяк флот атом су асты крейсеры командиры өлкән ярдәмчесе, командиры. 2001 дән Төньяк флот су асты көймәләре берләшмәсе командиры урынбасары. 2006 дан Тын океан флотында, уку-укыту фәнни үзәге башлыгы урынбасары. 2010 нан Төньяк флот, 2013 тән Тын океан флоты су асты көчләре командующие. 2016–19 да Балтыйк флоты штабы башлыгы, командующийның 1 нче урынбасары. 2019 дан Россия Хәрби-Диңгез Флоты башкомандующиеның кораллану буенча урынбасары.

**МӨХӘММӘ́ТШИНА** Резеда Фаил кызы (23.1.1964), педагог, пед. фән. д-ры (2008), проф. (2011). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1985), 2 нче Казан пед. көллиятендә укыта. Казан ун-тының Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр ин-тында Чит ил һәм рус филологиясе Югары мәктәбе директоры. Хезмәтләре башка телдә сөйләшүчеләргә рус теле һәм әдәбиятын укыту, белем бирүдә интерактив технологияләр, билингваль һәм мультилингваль укыту һәм мәктәпкәчә балалар һәм кече яшьтәге мәктәп укучыларының үсеш мәсьәләләренә карый. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2010).

**МУСАБӘ́КОВА** Рәисә Рәшит кызы (8.8.1952, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. канд. (2001). Казан ун-тын тәмамлый (1975). 1991 елга кадәр проектлау һәм төзелеш оешмаларында эшли. 1991 дән «Вечерняя Казань» г-тасында тәрҗемәче (рус теленнән татар теленә), 1992 дән ТР ФА Татар энциклопедиясе ин-тында, 1999–2014 тә тел белеме һәм әдәбият бүлеге мөдире. Бер үк вакытта, 2002–11 дә, Казан ун-тында укыта. «Сәгыйть Сүнчәләй: язмышы һәм иҗаты» монографиясе (2001), татар шагыйрьләре, прозаиклары һәм әдәбият галимнәренә (М.Гафури, М.Җәлил, М.Мәһдиев, Р.Фәйзуллин, А.Сайганов, Ф.Сафин, Б.Сөләйманов, Л.Йосыпова) багышланган, татар әдәбиятында милли характер, әдәби тәрҗемә мәсьәләләренә караган мәкаләләр авторы.

**НАДЕ́ЕВА** Марина Иосифовна (17.12.1955, Казан), педагог, тарих фән. канд. (1987), пед. фән. д-ры (1998). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1978). Казан технол. милли тикшеренү ун-тында укыта, социаль эшләр, пед. һәм психол. каф. профессоры. Хезмәтләре югары техник белем бирүне гуманитарлаштыру; дөньякүләм диннәрнең философиясе, психологиясе, этикасы, сәнгати мәдәнияте мәсьәләләренә карый.

**НӘБИ́ЕВ** Рөстәм Фәнис улы (21.5.1963, Алабуга ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2015). Курган югары хәрби-сәяси авиация уч-щесен (1989), Казан ун-тын (1992) тәмамлый. 1994–95 елларда ТР Эчке эшләр министрлыгының Җәзалар үтәтү идарәсендә рота командирының шәхси состав б-н эшләү буенча урынбасары. 1996–98 дә ТР Эчке эшләр министрлыгының Җәзалар үтәтү Федераль хезмәте идарәсенең Уку-укыту үзәге укытучысы. 1998 дән РФ Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик ин-тында, проф. (2014 тән). Хезмәтләре Алтын Урда, урта гасырлар төрки дәүләтләре тарихына, ш.у. хокук тарихына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**НӘБИУ́ЛЛИНА** Римма Рафаэль кызы (21.2.1967, Казан), психиатр, мед. фән. д-ры (2006). Казан мед. ин-тын тәмамлаганннан соң (1990), шунда ук психиатрия кафедрасында эшли. 1992 елдан «Радиоприбор» з-дының сан. частенда. 1994 тән Казан мед. академиясенең психиатрия, наркология һәм психотерапия кафедрасында, каф. профессоры (1997 дән). Хезмәтләре психик эшчәнлек б-н бәйле соматик тайпылышларга, ревматик артритлы авыруларда калкансыман биз гиперфункциясе очракларындагы психик тайпылышларга диагноз кую, авыруны дәвалау һәм кисәтү ысулларын эшләүгә карый.

**НӘГЫ́ЙМОВА** Айсылу Мирзариф кызы (19.11.1962, Актаныш р-ны Иске Байсар а.), социолог, социол. фән. д-ры (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1987), шунда ук эшли. Хезмәтләре хезмәт психологиясе, инженерлык психологиясе, эргономика, идарә социологиясе, демография һәм социол. мәсьәләләренә карый.

**НӘҖМИ́ЕВА** Миләүшә Тәлгать кызы (17.10.1964, Казан), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2019). Казан театр уч-щесен (1987), Көнчыгыш икътисади-юридик гуманитар академиясен (2008, Уфа ш.) тәмамлый. 1987 елдан Татар драма һәм комедия театрында эшли. Комик һәм драматик рольләр башкару остасы: Шәмси («Назлы кияү», К.Тинчурин), Сәкинә («Өти балак Гөлүзә», Ю.Әминев), Роза («Бәйрәм белән, кызлар», Ш.Фәрхетдинов), Иркә («Әстәгъфирулла», Н.Гаетбай), Алсу, Шәмсия («Гашыйклар тавы», «Мәкәрҗәгә барган идек», И.Юзеев), Банат («Кияүләр», Х.Вахит), Сәрия («Яшьлек хатам — йөрәк ярам», Д.Салихов), Сөембикә («Сөембикә егет сайлый», Ф.Яруллин), Магдалена («Өметсез хыяллар», Ф.Г.Лорка), Алчәчәк («Ак күгәрченнәр», Р.Батулла) һ.б.

**НЕБОЛЬСИНА́** Маргарита Викторовна (4.1.1955, Казан – 4.1.2020, шунда ук), филолог, язучы, филол. фән. канд. (2012), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2015). Казан ун-тын тәмамлый (1979). 2007–13 елларда ТР ФА кадрлар секторының әйдәп баручы белгече, 2013 тән матбугат секретаре. 2017–19 да ТР Милли музееның Бөек Ватан сугышы музей-мемориалында өлкән фәнни хезмәткәр, 2019 дан М.А.Балакирев исем. балалар сәнгать мәктәбендә тарих, мәдәният һәм сәнгать бүлеге мөдире. Н.ның проза әсәрләре «Казань», «Идел», «Казанский альманах» ж-лларында басыла. «И, Ходаем, чәнечкеле куакка атма мине!» («Господи, не бросай меня в терновый куст!», 2009), «Яшәүнең мәгънәсен аңларга тырыштым мин...» («Смысл жизни разгадать пытался я...», 2011), Бөек Ватан сугышында катнашучыларга багышланган «Сугыш...Язмышлар...Хәтер...Җырлар» («Война...Судьбы...Память...Песни...», 2015, Б.Л.Хәмидуллин б-н берлектә), «Рөстәм Кутуй» («Рустем Кутуй», 2016) китаплары авторы. Татарстанның Рус прозасы анталогиясен («Когда вернусь в Казанские снега», 2014, Р.Р.Сабиров б-н берлектә) төзи. Халыкара «Кутуй-фест» фестивален оештыручы һәм җитәкчесе (2016 дан). ТР Язучылар берлеге әгъзасы (2011). Медальләр б-н бүләкләнә.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Рөстәм Мөхәммәт улы (11.11.1937, Казан), йорт куяннары һәм болан асрау өлкәләре белгече, а.х. фән. д-ры (2012). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1962), 1965–73 елларда шунда ук генетика һәм а.х. терлекләре үрчетү кафедрасында эшли. 1962–64 тә Питрәч р-ны Кощаково җәнлек үрчетү с-зы зоотехнигы. 1974–78 дә Төмән өлкәсе Төмән р-ны «Рощинский» куян асраучылык с-зында директор урынбасары, 1979–82 дә Ямал а.х. тәҗрибә с-зында директор урынбасары (Ямал-Ненец автономияле округы, Салехард ш.), 1983–86 да Урал а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты өлкән фәнни хезмәткәре (Свердловск ш.), 1987–92 дә Татарстан нәселле терлек үрчетү совхозлары берләшмәсе баш зоотехник-селекционеры (Казан), 1993–2003 тә Татарстан дәүләт нәселле терлек үрчетү берләшмәсе өлкән зоотехнигы, 2004 тән РФА КГҮнең Энергетика проблемалары тикшеренү үзәгендә әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре йорт куяннары һәм төньяк боланнарын нәселдәнлек, үрчемлелек һәм үсү интенсивлыгы ягыннан бәяләү һәм сайлап алу, РФдә үрчетелә торган төп йорт куяннары токымнарының биол. һәм продуктлылык сыйфатларын чагыштырма бәяләү ысулларын камилләштерүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**НИКОЛА́ЕВА** Евгения Михайловна (10.11.1965), философ, филос. фән. д-ры (2007), проф. (2012). Казан ун-тын тәмамлый (1989). Хезмәтләре социаль, мәгариф, фән философиясе, социаль синергетика мәсьәләләренә карый. «Учёные записки Казанского университета. Гуманитарные науки» ж-лы редколлегиясе, Россия филос. җәмгыяте әгъзасы (2015).

**НИКОЛА́ЕВА** Наталия Геннадьевна (15.6.1973, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2009), проф. (2018). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1995), шунда ук эшли. 2011 елдан Казан мед. ун-тында, латин теле һәм мед. терминологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре рус теле тарихы, рус теленең лексик-семантик үзенчәлекләренә латин теленең йогынтысы, славян сүз ясалышы, дини уку йортларында рус әдәбияты укыту мәсьәләләренә карый. Мед. югары уку йортларында белем алучы студентларга рус, латин, борынгы грек телләрен өйрәтүгә, мед. терминнарына караган уку-укыту–методик ярдәмлекләр авторы.

**НОГМА́НОВА** Людмила Николаевна (20.05.1954, Зәй р-ны Төги а.), педагог, пед. фән. д-ры (2011), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (2001). Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), Әлмәт шәһәре мәктәпләрендә укыта, 1985–87 елларда Әлмәт шәһәре мәгариф бүлеге мөдире, 1987–91 дә Әлмәт нефть техникумы директоры, 1994–96 да Казандагы 80 нче мәктәп директоры, 1996–99 да Казан шәһәре хакимияте мәгариф идарәсенең Фәнни-методик үзәге директоры. 1999–2002 дә Казан шәһәре Вахитов р-ны мәгариф бүлеге башлыгы, 2002–2013 тә ТР мәгариф һәм фән министры урынбасары, бер үк вакытта, 2009–13 тә, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе, 2013–16 да Казан ун-тының Югары уку йортына кадәрге, гомуми һәм пед. белем бирү департаменты директоры, ректор киңәшчесе. 2016–2018 дә «ТИСБИ» идарә ун-ты ректоры, 2018 дән ТР Мәгарифне үстерү ин-ты ректоры. РФнең мактаулы мәгариф хезмәткәре (2018). Медальләр б-н бүләкләнә.

**НУРМЕ́ЕВ** Илдар Наил улы (11.9.1976, Казань), табиб, йөрәк-кан тамырлары хирургы, мед. фән. д-ры (2011). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2015). Казан мед. ун-тын тәмамлый (1999). 2002 елдан Респ-ка балалар клиник хастаханәсенең йөрәк-кан тамырлары бүлеге хирургы, бер үк вакытта, 2007 дән, Казан мед. ун-тының балалар хирургиясе кафедрасында, доцент (2015 тән). Студентлар өчен уку-укыту ярдәмлекләре авторы. Фәнни тикшеренүләре балаларны хирургик юл б-н дәвалауга, балаларда корсак ярысы арты веналары патологиясен, варикоз авыруын, гемангиомаларны, тромбозларны ачыклау һәм дәвалауга карый. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы бар. РФнең Балалар хирурглары һәм Йөрәк-кан тамырлары хирурглары ассоциацияләре әгъзасы.

**НУРУ́ЛЛИН** Эдуард Мингали улы (2.1.1966, Казан), джаз-оркестр артисты, инструменталист (бәрмә музыка уен кораллары), педагог, ТРның халык артисты (2017). Казан музыка уч-щесен (1985), Казан консерваториясен (1990, И.Ф.Сабирьянов классы) тәмамлый. Сәхнә эшчәнлеген 1986 елда В.Деринг җитәкчелегендәге ТР Дәүләт кинематография оркестрында башлап җибәрә. Бер үк вакытта, 1989 да, «Симха» еврей музыкасы клезмер ансамбле артисты (сәнгать җитәкчесес Л.Сонц). Н. ш.у. Казанның балалар музыка мәктәпләрендә бәрмә музыка уен кораллары буенча дәресләр бирә. 2011 дән ТР филармония джаз-оркестрында (ТР Дәүләт эстрада-симф. оркестры б-н ТР Дәүләт кинематография оркестры кушылу нигезендә барлыкка килә). Н. Россия шәһәрләре һәм чит илләр буйлап гастрольләрдә йөри, бөтенроссия һәм халыкара джаз, еврей музыкасы фестивальләрендә, мәдәният һәм сәнгать декадаларында һ.б.да катнаша. Оркестрда эшләү дәверендә Н. Россиянең халык артистлары (И.Бутман, А.Кролл, Д.Голощекин, В.Пономарев, А.Макаревич һ.б.), ш.у. дөнья джазы йолдызлары (Д.Роуленд, М.Гейнс, Э.Джонсон, Д.Дэвис, Л.Ульямс, Д.Майер һ.б.), бөтендөнья күләмендә танылган коллективлар (О.Лундстрем исем. Дәүләт камера джаз оркестры, «Нью-Йорк Войсес» вокаль ансамбле) б-н берлектә концертларда катнаша.

**ОСО́КИН** Денис Сергеевич (14.8.1977, Казан), сценарист, режиссёр. Казан ун-тын тәмамлый (2002). 2000–02 елларда Казан мәдәният идарәсе каршындагы Рус фольклоры үзәгенең сәнгать җитәкчесе. 2003–08 дә «Татарстан – Яңа гасыр» телеканалында режиссёр. 2013 тән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тының (хәзер Казан мәдәният ин-ты) Кино һәм телевидение ин-тында (хәзер кинематография һәм телевидение ф-ты) эшли. Документаль һәм нәфис фильмнар, ш.и. «Солы чыпчыклары» («Овсянки», 2010; иң яхшы сценарий өчен милли «Ника» кинематография бүләге, 2010; Азия–Тын океан кино академиясе призы, 2011), «Болын мариларының күктәге хатыннары» («Небесные жёны луговых мари», 2013, иң яхшы сценарий өчен Россия «Кинотавр» кинофестивале бүләге) фильмнары, удмурт, чуаш, мордва, керәшен татарлар һ.б. халыкларның этнографиясенә багышланган телевидение тапшырулары авторы. Европа кино академиясе әгъзасы (2011).

**ПА́ВЛОВА** Аделия Вадимовна (3.7.1974, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2011), проф. (2012). Казан финанс-икътисад ин-тын (1995), Бөекбритания ачык ун-тының эшмәкәрлек мәктәбен (1999) тәмамлый. 2001–2009 елларда «ПТК» ҖЧҖдә икътисад, коммерция һәм оештыру үсеше буенча ген. директор урынбасары, 2009–13 тә ген. директор. 2018 дән Казан эшмәкәрлек мәктәбе ген. директоры. Хезмәтләре идарә консалтингына, эшмәкәрлек өлкәсендә белем алу мәсьәләләренә карый.

**ПАНКО́В** Игорь Олегович (5.6.1953, Казан), травматолог, мед. фән. д-ры (2008), проф. (2013), Россия Табигыять белеме академиясенең хакыйкый әгъзасы (2013). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1975). 1976–77, 1981–83 елларда Казан шәһәре 15 нче клиник хастаханәсендә эшли. 1983 тән Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү үзәгендә (2009 дан Респ-ка клиник хастаханәсе составындагы Травматология үзәге), 2009 дан фәнни-тикшеренү бүлеге баш фәнни хезмәткәре, клиника җитәкчесе, бер үк вакытта, 2016 дан, Казан мед. академиясенең травматология һәм ортопедия каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешен очлык сөякләре сыну очракларында буыннарны хирургия юлы б-н дәвалау, буын эче җәрәхәтләре һәм очлыкларның эре буыннарында ортопедик авырулар очракларында терәк-динамик функцияләрне торгызуга карый. Уку-укыту–методик ярдәмлекләр авторы. Уйлап табуга 21 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ПЕТРУ́ШИН** Сергей Владимирович (27.8.1959, Мари Респ-касы Юрино штп), психолог, психол. фән. д-ры (2011). Казан төзүче инженерлар ин-тын (1981), Ленинград ун-тын (1990) тәмамлый. 1985 елдан Казан ун-тында: пед. каф. каршындагы психол. лаб-ясендә инженер, фәнни-тикшеренү лаб- ясендә фәнни хезмәткәр (1993), психол. кафедрасында укыта (1996–97), гомуми психол. каф. доценты (2012 дән). Мәскәү социаль идарә академиясенең гомуми психол. һәм пед. каф. профессоры (2015–16). Хезмәтләре социаль-психол. тренингның күпсанлы төркемдә аралашуда хәбәрдарлык үсеше чарасы булуы мәсьәләләренә карый. Проф. психотерапевтлар лигасы хакыйкый әгъзасы, Халыкара психол. фәннәре академиясе мөхбир-әгъзасы, Европа реестры психотерапевты.

**ПЛО́ТНИКОВА** Әдия Миначетдин кызы (1.1.1957, Чуаш АССРның Батыр р-ны Кыр Бикшиге а.), микробиолог, вирусолог, вет. фән. д-ры (2007), проф. (2018), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2011). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1986). 1978 елдан Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (2004 тән Хайваннарның токсикологик, радиацион һәм биол. куркынычсызлыгы федераль үзәге) микробиол. лаб-ясе лаборанты, өлкән лаборант, кече фәнни хезмәткәр, фәнни хезмәткәр, өлкән фәнни хезмәткәр, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, 2009 дан күзәнәкләр культурасы һәм тукландыргыч чаралар лаб-ясе мөдире, бер үк вакытта, 2018 дән, Казан инновацион ун-тының технол. һәм җәмгать туклануын оештыру кафедрасында. Фәнни эшчәнлеге вет. микробиологиясе һәм биотехнологиясенә, бруцеллёз һәм терлекләрнең башка аеруча куркыныч йогышлы авыруларына диагноз кую ысулларын һәм чараларын эшләүгә карый. Методик ярдәмлекләр авторы. Уйлап табуга 12 патенты бар, 11 рационализаторлык тәкъдиме кертә. ВДНХның көмеш медале б-н бүләкләнә (1990).

**ПОДАВА́ЛОВ** Владлен Борисович (14.07.1974, Баулы ш.), геолог-нефтьче. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2017). Казан ун-тын тәмамлый (2000). В.Д.Шашин исем. «Татнефть» гаммәви АҖ «Баулынефть» НГДУының баш геологы–идарә башлыгы урынбасары. 2018 елдан «Азнакайнефть» НГДУында, геол. һәм нефть, газ чыганакларын эшкәртү башлыгы урынбасары. П. тарафыннан нефтьнең карбонатлы кол-

лектор запасларын эшкәртү ысуллары тәкъдим ителә. Баулы нефть чыганагында доманик утырмаларыннан нефть чыгаруны тизләтү технологияләрен өйрәнү һәм эшкәртү буенча тәҗрибәләр үткәрелә. Дәүләт бүләге ТРның нефть чыганакларында нефть чыгару темпларын һәм нефть алу күләмен арттыру өчен технологияләр комплексын эшләүдә һәм аларны сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ПОСТАЛЮ́К** Михаил Петрович (13.4.1944, Киев өлкәсенең Поллеский р-ны Тарасы а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2007), проф. (2008). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында пропаганда бүлеге инструкторы булып эшли. 1978–88 елларда Казан мәдәният ин-тының иҗтимагый дисциплиналар (сәяси икътисад курсы буенча) каф. доценты, 1989–95 тә Казан финанс-икътисад ин-тының икътисад теориясе каф. доценты, мөдире. 1995 тән «ТИСБИ» идарә ун-тында икътисад теориясе һәм инновацияләр каф. мөдире, икътисад ф-ты деканы (1995–2005 тә). Хезмәтләре инновацияләү теориясе һәм практикасы мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**ПРО́ХОРОВА** Татьяна Геннадьевна (13.6.1954, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1978 елдан шунда ук эшли. Хезмәтләре 20–21 йөзләр рус әдәбиятына, Б.Пастернак, А.Ахматова, М.Цветаева, М.Булгаков иҗатларына, яңа рус прозасына карый. Лодзи шәһәре (Польша) ун-тында нәшер ителүче «Acta universitatis lodziensis. Folia litteraria rossica» ж-лы рецензент-эксперты (2014 тән).

**ПРУСАКО́В** Владимир Фёдорович (17.6.1956, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (2001). Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1979), Казандагы балалар мед. учреждениеләрендә эшли. 1987 елдан Казан мед. ун-тының балалык яшендәгеләр невропатологиясе кафедрасында, 2010 нан каф. мөдире. Хезмәтләре нерв системасы тайпылышлары булган балаларда нәселдән килгән матдәләр алмашы бозылуны өйрәнүгә карый. Балаларда кулбаш поясы амиотрофиясенә диагноз кую һәм авыруны дәвалау һ.б. ысулларны тәкъдим итә.

**РАЗУМО́ВСКАЯ** Елена Михайловна (28.10.1961), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2000), проф. (2006). Казан дәүләт финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1984). Казан ун-тының Идарә, икътисад һәм финанслар ин-тында эшли, социаль өлкә менеджменты каф. мөдире. Хезмәтләре икътисад һәм халык хуҗалыгы б-н идарә итү мәсьәләләренә карый.

**РӘХИ́МОВ** Сөләйман Туктар улы (30.6.1960, Әстерхан ш.), тарихчы, хакимият хезмәткәре. Әстерхан пед. ин-тын (1983), РФ Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте академиясен (Мәскәү, 2002) тәмамлый. 1991 елдан «Казан» милли мәдәният үзәгендә тарих бүлеге мөдире, 1994 тән ТР Үзәк дәүләт архивы директоры урынбасары, 1998 дән Казан шәһәре халык депутатлары Советының халыкара һәм муниципальара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы, 2006 дан ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр ком-ты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире, 2016 дан ТР Дәүләт архивы директоры, 2018 дән Болгар ислам академиясенең Ислам мирасы үзәге җитәкчесе. Хезмәтләре Россиядә яшәүче татар һәм төрки халыкларның халык мәгарифе тарихына, төрки-татар чыганакларын, тарихи шәхесләрне, Түбән Идел буе төбәген өйрәнү мәсьәләләренә карый.

**САБИРҖА́НОВ** Идрис Фидаимөхәммәт улы (8.12.1954, Йошкар-Ола ш.), оркестр солисты, концертмейстер, педагог, ТРның халык артисты (2015). Йошкар-Ола музыка уч-щесен (1974), Казан консерваториясен (1978) тәмамлый. 1977 елдан Казан консерваториясендә: бәрмә музыка уен кораллары махсус классын алып бара; бер үк вакытта, 1979 дан, И.В.Әүхәдиев исем. Казан музыка колледжында, 1990 нан Казан консерваториясе каршындагы урта махсус музыка мәктәбендә (колледжында) эшли. Татар филармониясендә (1975–95), Татар опера һәм балет театрында (1995 тән) бәрмә музыка уен кораллары симф. оркестры солисты һәм концермейстры. Бөтенсоюз, халыкара конкурсларда катнаша һәм төрле елларда жюри әгъзасы булып тора. Р.Беляков, Р.Кәлимуллин, Л.Любовский һ.б.ның әсәрләрен башкара һәм аларның аудиоязмаларын булдыра.

**САДЕТДИ́НОВ** Шияздан (Шейиздан) Вазыйх улы (16.12.1949, Мәскәү өлкәсенең Звенигород ш.), химик, химия фән. д-ры (1999), проф. (2001), Чуаш АССРның атказ. уйлап табучысы (1983). Чуаш пед. ин-тын (1973), Кама физик культура ин-тын (2000) тәмамлый. 1983 елдан Чуаш пед. ин-тының химия кафедрасында: доцент, 1986–96 да каф. мөдире; 1997 дән Кама физик культура ин-тының Яңа Чабаксар вәкиллеге директоры; 2007 дән Мәскәү автомобиль юллары ин-тының Волжск ф-лында (Чабаксар ш.): табигыять фәннәре дисциплиналары, 2011 дән табигыять фәннәре һәм техносфера куркынычсызлыгы дисциплиналары кафедралары мөдире; 2015 тән Һөнәри мәгариф ин-ты ректоры; 2017 дән Чуаш ун-тының материаллар белеме һәм металлургия процесслары каф. профессоры. Фәнни тикшеренүләре боратлы, фосфатлы, азотлы һәм силикатлы кушылмалар катнашындагы су-тоз системаларының физик-химик анализларына, шулар нигезендә коррозиягә каршы композицияләр, металл өслекләр өчен синтетик чистарту чаралары, металл эшкәртү өчен майлагыч-суыткыч сыеклыклар, коелма эшләнмәләр өчен форма ясау һәм җылылык саклау катнашмалары эшләүгә карый. Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Чуашия комсомолының фән һәм техника өлкәсендәге бүләге лауреаты (1980).

**САДРИ́ЕВ** Раил Илдар улы (14.10.1966, Буа р-ны Адав-Толымбай а.), актёр, режиссёр, педагог, ТРның халык артисты (2018). Казан ун-тын тәмамлый (1993). 1993–98 елларда Татар акад. театры иганәчесе, 1998–2000 дә — Мәскәү социаль-гуманитар ун-ты вәкиллегендә, 2000–02 дә Казан социаль-юридик ин-тының Буа һәм Тәтеш ф-лларында укыта, 2002–07 дә Буа халык театрының баш режиссёры, 2007 дән Буа драма театрының сәнгать җитәкчесе һәм директоры. Куйган спектакльләре: «Эх, кызлар», «Кияүләр» (Т.Миңнуллин), «Бәхеткә биш минут» (Л.Лерон), «Арыслан булса Сарбай», «Квартет» (Х.Ибраһим), «Кодалар, кодачалар» (С.Латыйпов), «Алсу томан» (Р.Сәгъди), «Бер сәгатькә ир кирәк» (А.Әхмәтшина), «Люкс № 13» (Р.Куни), «Примадонна» (К.Людвиг) һ.б. Д.Сираҗиев исем. театраль бүләк лауреаты (2015).

**САЙХУ́НОВ** Марат Вәлиулла улы (30.3.1970, Апас р-ны Морзалар а.), невролог, мед. фән. канд. (2009), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1993). 1993–99 елларда Казан шәһәре 6 нчы клиник хастаханәсендә табиб-невролог. 2000 нән Төбәкара клиник диагностика үзәгенең неврология бүлегендә, 2004 тән бүлек мөдире. Төбәкара клиник диагностика үзәгенең неврология хезмәте һәм Респ-ка кан тамырлары авырулары үзәге җитәкчесе. Фәнни тикшеренүләре баш миендәге кан тамырлары авыруларына диагноз кую, авыруларны дәвалау һәм кисәтүгә карый. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында баш мие кан әйләнеше кискен бозылган авыруларга медицина ярдәме күрсәтү» хезмәтен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**СА́РЧИН** Рамил Шәүкәт улы (14.12.1975, Ульянов өлкәсенең Барыш р-ны Калда а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2019). Ульянов пед. ун-тын тәмамлый (1998). 1998–2007 елларда мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укытучысы, директор урынбасары, 2007–11 дә Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында эшли, 2011–15 тә кабат мәктәптә, 2015 тән ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-тында. Хезмәтләре әдәби тәнкыйть, сәнгать белеме, рус һәм татар әдәбиятлары тарихы, энциклопедистика, төбәкне өйрәнү мәсьәләләренә карый. Шигъри җыентыклар, монографияләр авторы. «Әдәби Чистай» («Чистополь литературный», Н.М.Вәлиев б-н автордашлыкта, 2017) энциклопедиясен төзүче. РФ һәм ТР Язучылар берлекләре әгъзасы (2009, 2011), Финляндиянең рус телле әдәбиятчылары берлеге әгъзасы (2010).

**СӘЕТЗАДӘ́** Закир (1881–1918), театр тәнкыйтьчесе, драматург, педагог. Казанда беренче татар театр труппаларын оештыручыларның берсе. «Бичара Бибиҗиһан» (1908) мелодрамасы авторы. Казанны ак чехлар алганда фаҗигале төстә һәлак була.

**СӘФӘРГАЛИ́ЕВА** Фәрдия Фәтхрахман кызы (10.3.1953, Арча р-ны Урта Бирәзә а.), сценарист, режиссёр. ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2003). Казан пед. ин-тын (1976),

Казан мәдәният һәм сәнгать академиясен (1998) тәмамлый. 1976–92 елларда Ульянов шәһәре мәктәпләрендә укыта. 1992–98 дә «Казан» милли мәдәният үзәгендә мәдәни чаралар буенча инструктор, бүлекнең сәнгать җитәкчесе, Б.Урманче музее директоры, 1998–2004 тә Татар филармониясендә сәхнәгә куючы режиссёр, директор урынбасары. 2005–11 дә Татар яшь тамашачылар театрының әдәби-драматик бүлеге җитәкчесе. 2012 дә ТР Язучылар берлегендә пропаганда бүлеге җитәкчесе. Концерт программалары алып бара.

**СВИ́РИНА** Анна Андреевна (1.1.1978, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2011). Казан техник ун-тын тәмамлаганнан соң (2001), шунда ук эшли. 2007 елдан Казан техник ун-тының Чистай «Восток» ф-лында: укытучы, икътисад һәм идарә каф. мөдире (2011–17), директор (2017 дән).

**СЕМЁНОВ** Вячеслав Энгельсович (28.7.1970, Казан), химик, химия фән. д-ры (2015), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2014). Казан ун-тын тәмамлый (1992). 1996 елдан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-ты нуклеотидлы нигезләр лаб-ясендә: фәнни, өлкән фәнни хезмәткәр, мөдир (2014 тән), баш фәнни хезмәткәр (2017 дән); Казан милли тикшеренү технология ун-тының физик һәм коллоидлар химиясе каф. профессоры (2016 дан). Хезмәтләре биш һәм алты буынлы гетероцикллар чыгарылмаларының, аерым алганда, пиримидиннарның һәм триазолларның синтезы, төзелеше һәм физиол. активлыгы мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 5 патенты бар.

**СЕРГЕ́ЕВ** Сергей Алексеевич (7.4.1963, Казан), политолог, сәясәт. фән. д-ры (2006), проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1985). 1995 елдан Казан технол. ун-тында, социаль һәм сәяси конфликтология каф. профессоры (2007 дән). Хезмәтләре сәяси оппозиция, сәяси элита, яшьләр субмәдәнияте мәсьәләләренә карый.

**СИРА́ЕВА** Сәвия Гыймаделислам кызы (5.1.1934, БАССРның Нуриман р-ны Иске Исай а.), драма актрисасы, режиссёр. БАССРның һәм ТРның халык (1989, 2000), РФнең атказ. (2007) артисты. Уфа театр-сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1952), Башкорт филармониясендә эшли. 1960–63 елларда Салават драма театры актрисасы (Башкортстан), 1964 тән Башкорт акад. драма театрында, 1989 дан Уфа яшь тамашачылар театрында, 1993 тән Уфа татар «Нур» театрында. Үткен характерлы һәм комик рольләрне зур уңыш б-н башкара. Аеруча зур рольләре: Җиһан, Сабира («Башмагым», «Кыз урлау», М.Кәрим), Гөлирә («Әманәткә хыянәт», Ф.Богданов), Тайфә («Өч аршын җир», А.Гыйләҗев), Разия («Ай булмаса, йолдыз бар», Т.Миңнуллин), Сихерче (шул исем. әсәр буенча, Н.Гыйматдинова), Әни («Әни килде» («Әниемнең ак күлмәге»), Ш.Хөсәенов), Сәйдә («Ал җаным-ны, әфәндем», А.Нәсин). Режиссёр буларак, «Нур» театрында «Урман әкияте» (С.Кудаш) спектаклен куя. ТР Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1987).

**СКВОРЦО́В** Артём Эдуардович (16.4.1975), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1997), шунда ук эшли, доцент (2009 елдан). Хезмәтләре рус әдәбияты мәсьәләләренә карый. «Эврика» (2008), «Anthologia» (2011), «Белла» (2016) әдәби бүләкләре лауреаты.

**СКРЯ́БИН** Сергей Маркович (30.11.1961, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1984), шунда ук алгебра кафедрасында, бер үк вакытта, 2000 елдан, Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. Хезмәтләре гомуми теоретик-бәйләнешле конструкцияләр нигезендә картан тибындагы Ли алгебралары теориясен эшләүгә, уңай характеристикалы кырларга карата чикләнгән үлчәнешле Ли алгебраларын классификацияләүгә, Хопф алгебраларының структур үзлекләрен, аларның ассоциатив алгебраларга тәэсирен тикшерүгә карый. Коммутатив бәйләнешләргә карата картан тибындагы Ли алгебралары изоморфизмнарын һәм бу алгебраларның йомык булмаган алгебраик кырларга караган формаларын сурәтли. Классик инвариантлар теориясенең күп кенә фундаменталь фактларын Хопф алгебрасы гамәлләренә күчерә. Хопф алгебрасының проективлыгы һәм яссылыгы турындагы теоремаларны исбатлый.

**СОЛОВЬЁВ** Сергей Иванович (15.8.1961, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1983), шунда ук хисаплау математикасы кафедрасында эшли. Хезмәтләре матем. физиканың нәсызыкча мәсьәләләрен якынча чишү алымнарына карый. Нәсызыкча мәсьәләләренең Гильберт фәзасында үз кыйммәтләренә карата чишелешләре барлыгын раслый, чикләнгән үлчәнешле аппроксимацияләрнең якынча хаталарын бәяли, чикле элементлар алымының якынча хаталарын тикшерә, асфәзаның бисекциясе һәм итерациясе алымнарын тәкъдим итә һәм нигезли, сызыкча алгебраик тигезләмәләр системасын чикле элементлар алымы б-н чишүнең турыдан-туры икътисади алгоритмнарын эшли.

**СОЛТА́НОВ** Дамир Рәфхәт улы (4.5.1975, Украина ССР, Донецк ш.), музыкант, педагог, ТРның атказ. артисты (2012). Донецк консерваториясен тәмамлаганнан соң (1997), шунда ук укыта. 1998 елдан Казакъ милли сәнгать ун-тында, кубыз һәм рус халык музыка уен кораллары каф. доценты, 2003–05 тә рус халык музыка уен кораллары каф. мөдире. 2005–10 да «Традицион музыка сәнгате» ф-ты деканы. Бер үк вакытта халыкара «Казакъстан баян-фест» баян сәнгате фестиваленең сәнгать җитәкчесе һәм директоры. «Дөнья аккордеоны мәтры» югары лигасы әгъзасы (2007). Актив концерт эшчәнлеге алып бара. Германия, Австрия, Франция, Италия һ.б. илләрдә узган халыкара конкурслар лауреаты. Казакъстан Респ-касының Дәүләт «Дарын» яшьләр бүләге (2000) һәм беренче Президенты фонды бүләге (2012) лауреаты.

**СОРО́КИНА** Лилия Валериевна (28.4.1973, Ворошиловград өлкәсенең Красный Луч ш.), балет артисты, биюче, балетмейстер, педагог, ТРның халык артисты (2016). Казан мәдәният һәм сәнгать академиясен тәмамлый (1996). 1990–96 елларда 11 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә нәфис гимнастика буенча тренер, 1996–2016 да ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә балет артисты, бер үк вакытта, 2006–07 дә, ансамбль каршындагы «Юлдаш» балалар вокаль-хореография студиясендә балетмейстер-куючы һәм педагог. 2017 дән «Преображение» балалар бию студиясе җитәкчесе, бер үк вакытта, 2018 дән, Казан мәдәният ин-тында укыта. Концерт репертуарын ансамбльнең бөтен әсәрләре тәшкил итә: Әстерхан, Мәскәү, Кырым, Уфа, керәшен татарларның биюләре, заманча вокаль-хореографик постановкалар: «Казан турында риваять» (Кош, Ана, Идел рольләрендә), «Истанбул хыяллары» (баш героиня ролендә), «Ак бүре» (Кош ролендә), «Төрки дөнья» (Ана бүре ролендә), «Ак морзалар» (соло), «Болгарның изге бакчалары» театральләштерелгән программасы (Ана ролендә) һ.б. Татарстан, Россия шәһәрләрендә һәм чит илләрдә концерт номерлары б-н чыгышлар ясый; халыкара, бөтенроссия фестивальләрендә катнаша. Медаль б-н бүләкләнә.

**СО́СОВ** Евгений Николаевич (7.7.1959, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), шунда ук (бүленеп) геом. кафедрасында (2007 елдан), бер үк вакытта Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында (2001–07) эшли. 1988–91 елларда Казан авиация ин-тында, 1991–2001 дә Казан пед. ун-тында эшли. Геодезик фәзаның кабарынкы һәм чикләнгән күплекләре геометриясен тикшерә. Хезмәтләре Лобачевский, метрик, гиперәслекнең орынмаларга катламланышы, сызыкчалы геометрияләргә карый.

**СӨЛӘЙМА́НОВ** Салават Шәех улы (25.9.1951, Хабаровск крае, Түбән Амур өлкәсенең Ульчский (Ульча) р-ны Учама а.), мед. фән. д-ры (1998), проф. (2000). Табигыять фән. академиясе хокукый әгъзасы (1999). Хабаровск мед. ин-тын (хәзер Ерак Көнчыгыш мед. ун-ты) тәмамлый (1978). 1981 елдан Хабаровск мед. ин-тының фармакология кафедрасында, 1994 тән каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1994 тән, проректор. 2001 дән Хабаровск крае Сәламәтлек саклау министрлыгының белгечләрнең белемен күтәрү ин-ты проректоры, 2006 дан ректор. Бер үк вакытта, 2002–13 тә, шунда ук клиник фармакология һәм патофизиол. каф. мөдире. 2013 тән «АЮСС–Лоджистик» ҖЧҖ дә мед. проектлары директоры, 2017 дән «САИКО» Россия–Япония мед. үзәге ген. директоры, 2018 дән шунда ук тышкы элемтәләр һәм проектларны үстерү буенча директор. Тикшеренүләре клиник фармакология, фармакогенетика, фармакоэпидемиологиягә, дәлилләү медицинасына, Төньяк, Себер һәм Ерак Көнчыгышның төп аз санлы халыклары мед.-социаль проблемаларына, Төньяк, Себер һәм Ерак Көнчыгышның төп аз санлы халыкла-

рының традицион медицинасын өйрәнүгә карый. «Здравоохранение Дальнего Востока» ж-лын оештыручы һәм баш мөхәррире (2002–11). Төньякның аз санлы халыклары мәсьәләләре буенча СССР ЮС эксперты (1989–91). Хабаровск крае Иҗтимагый палатасы әгъзасы (2012–16). Хабаровск крае халыклары ассамблеясы рәисе (2011–15). Хабаровск шәһәре татар-башкорт зыялылары клубы вице-президенты (2016 дан). Медальләр б-н бүләкләнә.

**СӨНГАТУ́ЛЛИНА** Халидә Мәгъфүрьян кызы (2.8.1965, БАССРның Илеш р-ны Этәй а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2019). Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тын тәмамлый (1994). 1989 елдан Казан татар яшь тамашачылар театрында эшли. Театр сәхнәсендә актриса тормышчан, кабатланмас драматик һәм үзенчәлекле комик образлар тудыра: Галимәбану («Галиябану», М.Фәйзи), Гүзәлия, Суфия («Нигез ташлары», «Кырларым-тугайларым», Т.Миңнуллин), Миңзифа («Кичер мине, әнкәй», Р.Батулла), Зәйтүнә («Тайгак кичү», И.Салахов), Баян («Оят төне», Б.Мукаев), Роза («Сандугачлар килгән безгә», И.Юзеев), Җиһан, Хаҗия («Башмагым», «Кыю кызлар», Т.Гыйззәт). С. балалар өчен Көрән, Куян, Кәҗә («Керпе малае дуслар эзли», «Бүре һәм Кәҗә», Р.Корбан), Убырлы («Мисс Убырлы», Ф.Галиев) һ.б. кызыклы образлар иҗат итә. ТР Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (2007).

**СПИРИДО́НОВ** Геннадий Николаевич (10.8.1957, Тәтеш р-ны Богдашкино а.), эпизоотолог, биол. фән. д-ры (2014). Буа вет. техникумын (1976), Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлый. 1976–81 елларда Минзәлә р-ны «Искра» к-зында, 1984 тән Пермь өлкәсенең Кишерт р-ны «Посадский» с-зында вет. табибе. 1989 дан Казан вет. ин-тының эпизоотология кафедрасында, 1990 нан 8 нче лаб-ясендә кече фәнни хезмәткәр, 1993 тән фәнни хезмәткәр, 2007 дән Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тынының (хәзер Хайваннарның токсикологик, радиацион һәм биол. куркынычсызлыгы федераль үзәге) эпизоотология лаб-ясе өлкән фәнни хезмәткәре, 2007 дән бактерияле инфекцияләр лаб-ясе мөдире. Фәнни тикшеренүләре вет. микробиологиясе, вирусология, эпизоотология һәм иммунологиягә карый. С. тарафыннан мөгезле эре терлекләрдә йогышлы кератоконъюктивитка диагноз кую, авыруны дәвалау һәм кисәтү буенча методик тәкъдимнәр әзерләп бастырыла. Уйлап табуга 12 патенты бар.

**СТЕПА́НОВА** Надежда Юльевна (9.6.1960, Казан), эколог, биолог-микробиолог, биол. фән. д-ры (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1982). 1983–86 елларда Казан күн җитештерү берләшмәсендә әйләнә-тирәне саклау буенча инженер, 1986–89 да Урта Идел бассейны инспекциясендә аналитика бүлеге башлыгы, 1989–92 дә ТРның Табигатьне саклау дәүләт ком-тында әйдәп баручы белгеч, 1992–2001 дә ТР Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау министрлыгы баш белгече, 2001–02 дә Казан ун-тының экология ф-тында фәнни хезмәткәр, 2002–04 тә Казан техник ун-тында сәнәгать каф. доценты, 2004 тән Казан ун-тының гамәли экология каф. мөдире, проф. (2009 дан). Тикшеренүләре сулык экосистемалары экологиясенә, экологик токсикология һәм микробиологиягә, халыкның сәламәтлеге һәм табигый экосистемаларга зыян килү куркынычы очракларын өйрәнүгә карый. ТР ФАнең В.А.Попов исем. премиясе лауреаты (2005). РФ Гидробиол. җәмгыяте әгъзасы (1986–2006), Халыкара токсикологлар җәмгыятенең (SETAC) Россия бүлеге әгъзасы (2013).

**СУДЫ́КИН** Александр Николаевич (25.4.1980, Бөгелмә ш.), инженер, техник фән. канд. (2014), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2015). Казан технол. ун-тын тәмамлаганнан соң (2003), Түбән Кама нефть эшкәртү з-дында. 2004 елдан ТатНИПИнефтьтә: нефть, газ һәм суны тикшерү һәм чыгаруга әзерләү бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре. Дәүләт бүләге югары үзле нефть чыгару буенча техник чаралар һәм технологияләр комплексын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 11 патенты бар.

**СУДЫ́КИН** Сергей Николаевич (25.4.1980, Бөгелмә ш.), инженер, техник фән. канд. (2011), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2015). Казан технол. ун-тын тәмамлаганнан соң (2003), Түбән Кама нефть эшкәртү з-дында. 2005–06 елларда «Фән» ҖЧҖдә инженер, 2006 дан ТатНИПИнефтьтә, нефть чыгару технологияләре лаб-ясе мөдире. Дәүләт бүләге югары үзле нефть чыгару буенча техник чаралар һәм технологияләр комплексын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 12 патенты бар.

**СУТЮ́ШЕВ** Мидхәт Усман улы (9.5.1926, Казакъстан АССР, Петропавловск ш. — 10.5.1996, шунда ук), радиотехник, сәнәгый җитештерүне оештыручы, җәмәгать эшлеклесе. Ленинград арктика уч-щесен тәмамлый (1949). 1942–46 елларда Петропавловск шәһәрендәге 641 нче з-дта эшли (1951 дә заводка С.М.Киров исеме бирелә). 1949–52 дә СССР МС Төньяк диңгез юллары Баш идарәсенең Поляр авиация идарәсендәге «Тикси» авиапортында радиотехник, өлкән радиотехник. 1953–61 дә С.М.Киров исем. з-дта мастер, өлкән инженер, цех башлыгы, бүлек башлыгы, директор урынбасары, 1961–87 дә директор. Заводны реконструкцияләү һәм техник яктан үзгәртеп коруга зур өлеш кертә. Петропавловскиның шәһәрдә төзелешне, сәнәгатьне үстерү, төзекләндерү эшләре, мәдәнияткә ярдәм мәсьәләләре б-н шөгыльләнүче пр-тиеләр директорлары советына җитәкчелек итә. 1980 елларда, пенсиягә чыкканнан соң, шәһәрнең ветераннар советын җитәкли. Петропавловскида беренче тапкыр Сабан туе уздыру, «Дуслык» татар-башкорт милли-мәдәни үзәге төзү эшләрендә башлап йөри. Казакъстан ССР Югары Советы депутаты. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Петропавловск шәһәренең мактаулы гражданы (1995).

**ТАЙШЕВА** Гүзәл Рәвгать кызы (11.5.1975, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2010), проф. (2011). Казан технол. ун-тын тәмамлаганнан соң (1998), шунда ук икътисад кафедрасында эшли. 2001–04 елларда Татарстан агробизнес кадрларын яңадан әзерләү ин-тында, 2005–11 дә Казан аграр ун-тының стат. һәм маркетинг кафедрасында укыта. Бер үк вакытта, 2005–2011 дә, Мәскәү шәһәре хөкүмәте каршындагы Мәскәү эшмәкәрлек ин-тында эшли. 2011 дән Казан инновацион ун-тының логистика кафедрасында. Хезмәтләре региональ икътисад, логистика һәм идарә, азык-төлек куркынычсызлыгы мәсьәләләренә карый.

**ТАЙМА́РОВ** Михаил Александрович (31.8.1947, Киров өлкәсенең Тужа р-ны Кече Торсала а.), технолог, техник фән. д-ры (1998), проф. (2000). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1971). 1971–73 елларда нефть химиясе машиналары төзү пр-тиеләрендә инженер; 1974–81 дә Казан төзүче инженерлар ин-тында, 1982–89 да Казан химия-технол. ин-тында эшли, 1990–94 тә СССР ФАнең Казан ф-лында өлкән фәнни хезмәткәр. 1997 дән Казан энергетика ун-тында. Хезмәтләре энергетика машиналары һәм җайланмалары өлкәсенә карый. Уйлап табуга 120 патенты бар.

**ТАРА́СОВА** Фәнүзә Харис кызы (28.5.1963, Чаллы ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2012). Алабуга пед. ун-тын тәмамлый (1985). 1985–93 елларда мәктәптә, 1993–2007 дә Чаллы пед. колледжында укыта, 2007–12 дә Чаллы пед. ун-тында, чит телләр ф-ты деканы, 2012–14 тә ТР Мәгарифне үстерү ин-ты ректоры, 2014 тән Казан ун-тының Филол. һәм мәдәниятара багланышлар ин-тында, роман-герман каф. мөдире. Хезмәтләре телләрне чагыштырып өйрәнүгә карый. Татар һәм рус телләре буенча тәрҗемә мәсьәләләренә караган уку-укыту–методик ярдәмлекләр авторы.

**ТАХТА́РОВА** Светлана Салават кызы (19.11.1967, Волгоград өлкәсе, Ленинск ш.) тел галиме, филол. фән. д-ры (2011). Волгоград ун-тын тәмамлаганнан соң (1991), шунда ук эшли. 1993–2000 елларда Волжск гуманитар ин-тында (Волгоград ун-ты ф-лы) укыта, 2000–12 дә шунда ук немец филологиясе каф. мөдире, 2012 дән Казан ун-тының Халыкара мөнәсәбәтләр ин-тында тәрҗемә теориясе һәм практикасы каф. мөдире. Хезмәтләре дискурс теориясенә, этно-, психо-, социолингвистика, когнитив лингвистика, коммуникативистика мәсьәләләренә карый, ш.у. уку-укыту–методик ярдәмлекләр авторы.

**УРА́ЗОВА** Гүзәл Әскәр кызы (8.1.1982, Пермь өлкәсенең Барда р-ны Барда а.), җырчы. ТРның халык (2019) һәм БРның атказ. (2019) артисты. Казан пед. ун-тын (2004), Мәскәү икътисад, стат. һәм информатика

ун-тын (2004), ТР Президенты каршындагы Дәүләт һәм муниципаль идарә академиясен (2009) тәмамлый. У. актив концерт эшчәнлеге алып бара. Татарстанда, Россиядә һәм чит илләрдә чыгышлар ясый. Репертуарын хәзерге заман һәм классик композиторларның җырлары тәшкил итә: «Гөлйөзем ариясе» (С.Сәйдәшевнең «Наёмщик» операсыннан), «Сусау», «Китмә, сандугач», «Зарыгу», «Әллә күрешәбез, әллә юк», «Нигә болай ашкынасың, йөрәк?», «Тимәсен тик күзләрем», «Гашыйк итеп сакла син» («Елның иң яхшы җырчысы» номинациясе), «Синсез үтте гомерем», «Язмыш йомгак сүтә» (икесе дә — «Елның иң популяр җырчысы» номинациясе), «Туган авылыма» һ.б. Халыкара «Татар җыры» конкурсы лауреаты (2002–04, 2006–19).

**УСЕ́НКО** Виктор Иванович (31.3.1950, Казан), гистолог, хайваннар онкологиясе һәм морфологиясе өлкәсе белгече, биол. фән. д-ры (2000), проф. (2001). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнан соң (1982), шунда эшли, 2001 елдан анатомия, патанатомия һәм гистология каф. профессоры. Фәнни тикшеренүләре мех өчен үрчетелә торган хайваннар организмының иммун, эндокрин һәм җенси системалары әгъзалары микроморфологиясен, тәҗрибәләрдә актив матдәләр кулланып, онтогенезда һәм эксперимент ярдәмендә өйрәнүгә карый. Уку-укыту ярдәмлекләре авторы.

**ФАДЕ́ЕВА** Ирина Дмитриевна (28.4.1966, Казан), орлыкчылык белгече, а.х. фән. канд. (2001). ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2011), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2015). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1988), ун-т каршындагы Ботаника бакчасында эшли, 1992 елдан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында көзге бодай селекциясе лаб-ясе мөдире, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре йомшак көзге бодай селекциясе, үсемлекләр иммунитеты, көзге бодайның игү технологиясе элементларын эшләү, бөртекнең технологик һәм икмәк пешерүгә ярашлы сыйфаты мәсьәләләренә карый. Уку-укыту–методик ярдәмлекләр авторы. Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касы шартларына яраклаштырылган бөртекле культураларның көндәшлеккә сәләтле сортларын булдыргану һәм гамәлгә кертүгә өчен бирелә.

**ФАЗЛЫ́ЕВА** Ләйлә Ринат кызы (29.5.1975, Кыргызстан ССР, Кант р-ны Кант пос.), хакимият эшлеклесе. Казан ун-тын (1997), Россия хокук академиясен (2012), Казан ун-тының Югары бизнес мәктәбен (2018) тәмамлый. 1996–2004 елларда Казан шәһәренең 126 нчы гомуми урта белем бирү мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы, директор урынбасары, 2004–07 дә Казан шәһәренең 15 нче мәктәбе директоры; 2007–11 дә Казан шәһәренең Совет р-ны хакимияте башлыгы урынбасары; 2011–14 тә Казан шәһәре башкарма ком-ты җитәкчесе урынбасары; 2014–18 дә ТР Президенты ярдәмчесе; 2018 дән ТР Премьер-министры урынбасары. РФнең мактаулы гомуми белем бирү хезмәткәре (2009). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ФАТЕ́ХОВА** Наилә Әсгать кызы (12.5.1962, Мәскәү), җырчы, композитор, продюсер. РФнең атказ. (2003), ТРның халык (2019) артисты. М.М.Ипполитов-Иванов исем. музыка уч-щесен тәмамлый (1985). 1980 елдан С.Хәбибуллин җитәкчелегендәге «Хыял» ансамблендә чыгыш ясый. 1986–88 елларда Мәскәү өлкә филармониясендә солист-вокалист, 1989–91 дә Х.Кужалиев җитәкчелегендәге «Эмират» ансамблендә оештыручы, текстлар һәм музыка авторы, вокалист, 1991–2005 тә Мәскәү өлкә филармониясендә вокалист. Репертуарын, нигездә, тарихи һәм дини темаларга багышланган җырлар тәшкил итә. 2006 да үзе оештырган «Мәдинә» ансамбле җитәкчесе, ш.у. «Рух» продюсерлык үзәге директоры һәм аның сәнгать җитәкчесе. Медаль б-н бүләкләнә.

**ФӘЙЗОВ** Таһир Һади улы (5.12.1948, Пермь өлкәсенең Көнгер ш.), биохимик, вет. фән. д-ры (1998), проф. (2004), ТРның атказ фән эшлеклесе (2017). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1971). 1976 елдан Вет. фәнни-тикшеренү үзәгендә (хәзер Хайваннарның токсикологик, радиацион һәм биол. куркынычсызлыгы федераль үзәге): кече фәнни хезмәткәр, өлкән фәнни хезмәткәр, биохимия һәм молекуляр-генетик анализ лаб-ясе мөдире. Бер үк вакытта, 2012–17 дә, Казан аграр ун-тының гомуми химия каф. мөдире. Уйлап табуга 8 патенты бар. Фәнни тикшеренүләре прокариотик һәм эукариотик күзәнәкләр молекуляр биологиясе һәм биохимиясенә, аеруча куркыныч инфекцияләр китерел чыгаручылар структурасын өйрәнүнең молекуляр-генетик технологиясенә, микроорганизмнарның протеомика һәм геномикасына карый.

**ФӘСХЕТДИ́НОВ** Рәшит Изахетдин улы (5.10.1947, Буа р-ны Килдураз а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТРның атказ. икътисадчысы (2000). Казан а.х. техникумын (1966), Казан финанс-икътисад ин-тын (1978) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген туган авылында «Коммуна» к-зы бухгалтеры булarak башлый. 1969–77 елларда Казан гарнизоны хәрби частенең фатир-файдалану хезмәте башлыгы булып эшли. 1977–84 тә Казанның Бауман р-ны азык-төлек сәүдәсе бүлеге директоры урынбасары, директоры. 1984 тән дәүләт хакимияте органнарында: 1984–87 дә Казанның Бауман р-ны башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1987–89 да ТАССР сәүдә министры урынбасары, 1989–99 да Казан шәһәр хакимияте башлыгы урынбасары. 1999–2005 тә ТАИФ ААҖ ген. директоры урынбасары. 2005 тән «Эдельвейс-групп» ААҖнең үсеш буенча директоры. Халык депутатларының Казан шәһәре Бауман р-ны советы (1984–87), Казан шәһәр думасы (2005–10) депутаты булып сайлана. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ФӘТХИ́ЕВ** Фарис Гаяз улы (13.10.1960, Актаныш р-ны Иске Җияш а.), хакимият-хуҗалык хезмәткәре. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2015). Лаеш а.х. техникумын, Казан а.х. ин-тын тәмамлый. 2007 дән «Әнәк» ҖЧҖ агрофирмасы директоры (Актаныш р-ны). Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касы шартларына яраклаштырылган бөртекле культураларның көндәшлеккә сәләтле сортларын булдырганы һәм гамәлгә кертүгә өчен бирелә.

**ФӘХРЕТДИ́НОВ** Шамил Габдрахман улы (22.5.1952, Казакъстан ССР, Кустанай ш.), педагог, режиссёр, Казакъстан Респ-касының атказ. мәдәният эшлеклесе (2008). Кызыл Урда пед. ин-тын (1974), Чиләбе сәнгать һәм мәдәният академиясен (2009) тәмамлый. 1988 елдан «Карнавал» бию ансамбле җитәкчесе, бер үк вакытта, 2007 дән, «Карнавал» хореография мәктәбе директоры (Кустанай ш.). Ф. җитәкләгән ансамбль — Казакъстан, Россия, Франция, Германия, Болгария, Польша, Венгрия һ.б. илләрдә уздырылган халыкара конкурслар һәм фестивальләрдә җиңүче. Казакъстан Респ-касының мактаулы мәгариф хезмәткәре (2006). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ФӘХРЕТДИ́НОВА** Лилия Раиф кызы (29.4.1966), психолог, психол. фән. д-ры (2012). Казан мед. ин-тын (1988), Казан ун-тын (1995) тәмамлый. 1995 елдан Казан ун-тының Психол. һәм мәгариф ин-тында эшли. Хезмәтләре гомуми психол., шәхес психологисе, психол. тарихы мәсьәләләренә карый. Психол. фәнендә яңа юнәлеш — борчылу-кайгыру (кичереш) теориясен булдыра.

**ХӘЙРЕТДИ́НОВА** Гөлшат Әхмәтхан кызы (27.2.1954, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), мәктәптә укыта. 1979 елдан Казан ун-тында эшли. Хезмәтләре тел берәмлекләренең эстетик ресурслары, рус теленең морфологик категорияләре, рус һәм чагыштырма грамматиканың актуаль проблемалары һ.б.га карый. Уку-укыту ярдәмлекләре, ш.у. гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслекләр авторы. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2010).

**ХӘЙРУ́ЛЛИНА** Йолдыз Рәкыйб кызы (1.5.1961, Казан), социолог, социол. фән. д-ры (1999), проф. (2002), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1983), шунда ук эшли. Хезмәтләре социол. теориясе, методологиясе һәм тарихына, социаль институтлар, икътисади социол. һәм демография мәсьәләләренә карый. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2008).

**ХӘМИДУ́ЛЛИНА** Гөлнара Рифкать кызы (15.7.1967, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2004), проф. (2010). Казан финанс-икътисад ин-тын (1988), «ТИСБИ» идарә ун-тын (2000) тәмамлый. 1991–97 елларда Мәскәү «Центросоюз» коопреатив ин-ты Казан ф-лының бухгалтер хисабы, анализ һәм стат. кафедрасында өлкән укытучы, 1997–98 дә Мәскәү коммерция ун-ты Казан коммерция ин-тының хисап, финанс һәм банк эше каф. доценты, 1998–2000 дә «ТИСБИ» идарә ун-тында фән эшләре буенча проректор, бухгалтер хисабы каф. мөдире, 2003–04 тә Мәскәү кооператив ун-тының Казан коо-

перативн ин-тында фән эшләре буенча проректор, бухгалтер хисабы каф. мөдире, 2004–07 дә Россия сәүдә-икътисад ун-тының Казан ф-лы директоры, директор урынбасары, 2007–10 да Татар гуманитар-пед. ун-тында фән эшләре буенча проректор, икътисад мәсьәләләре буенча ректор киңәшчесе, дәүләт һәм муниципаль идарә каф. мөдире, 2011 дән Казан ун-тының сыйфат идарәсе каф. мөдире. Хезмәтләре бухгалтер хисабы системасын камилләштерү мәсьәләләренә карый.

**ХӘСӘ́НОВ** (Хасянов) Олег Ренат улы (18.2.1983, Ульянов өлкәсенең Чардаклы р-ны Поповка а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2018). Ульянов пед. ун-тын тәмамлый (2005). 2006 елдан Ульянов аграр ун-тында: 2011 дән доцент, 2015–17 дә — социол. һәм тарих философиясе, 2019 дан — социаль-гуманитар һәм икътисад фәннәре каф. мөдире (бүленеп, 2015–17 дә «Ленин мемориалы» өлкә мәдәният учреждениесе гыйльми секретаре, 2017–18 дә Ульянов стратегик тикшеренүләр үзәгенең әйдәп баручы белгече). Хезмәтләре Урта Идел буе аграр тарихына карый.

**ХУ́ҖИН** Ринат Рәис улы (8.4.1955, Әлмәт р-ны Рус Акташы пос.), нефтьче-технолог, хуҗалык җитәкчесе, техник фән. д-ры (2010), РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (2010). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), «Татнефть» берләшмәсенең Әлмәт ятмаларның нефть бирүчәнлеген арттыру идарәсендә бораулаучы ярдәмчесе, бораулаучы, скважиналарны капиталь ремонтлау мастеры, өлкән мастер булып эшли. 1981 елдан «Әлмәтнефть» НГДУында технолог, өлкән инженер–нефть һәм газ чыгару цехы башлыгы урынбасары. 1983 тән КПССның Татарстан өлкә ком-тында нефть һәм химия сәнәгате бүлеге инструкторы. 1985 тән «Әлмәтнефть» НГДУында нефть һәм газ чыгару цехы, җитештерүгә хезмәт күрсәтү базасы башлыгы. 1997 дән «Иделойл» ААҖ баш инженеры, ген. директоры. 2006 дан «Карбон-Ойл» ҖЧҖ ген. директоры, бер үк вакытта, 2007 дән, «Благодаров-Ойл» ҖЧҖ директоры. Фәнни эшчәнлек алып бара: 2010 нан Әлмәт нефть ин-тының нефть һәм газ скважиналарын бораулау каф. профессоры, 2015 тән Удмурт ун-тының Нефть һәм газ ин-ты нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү һәм эксплуатацияләү каф. профессоры, 2018 дән Казан ун-тында өлкән фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре нефть һәм газ чыгару технологиясе мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 53 патенты бар. РФ Сәнәгать һәм энергетика министрлыгының мактаулы нефтьчесе (2004), РФ Ягулык-энергетика комплексы мактаулы хезмәткәре (2015). Медаль, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ХУ́ҖИНА** Лилия Булат кызы (15.7.1962, БАССРның Бәләбәй р-ны Знаменка а.), технолог, техник фән. д-ры (2007). Башкорт ун-тын тәмамлый (1984). 1984–2007 елларда Уфа нефть техник ун-тында, мәгълүмати технологияләр, матем. һәм табигыять фәннәре каф. профессоры (2007 дән). 2007 дән Әлмәт нефть ин-тының нефть һәм газ скважиналарын бораулау каф. профессоры, мөдире. «Сколково» фонды, «Углеводородларны чыгару һәм файдалану технологияләре» технол. платформасы эксперты. Казакъстан фәнни-тикшеренү техник ун-тында чит илдән чакырылган фәнни җитәкче (2016–19). Респ-ка «Ел хатын-кызы» конкурсының «Галимә» номинациясендә җиңүче (2014). Хезмәтләре бораулау колоннасының аскы өлеше динамикасы, горизонталь скважиналарны бораулаганда скважина көпшәсенең ышкылу коэффициентын киметү мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 14 патенты бар.

**ХУҖИХА́НОВ** Фәрит Вильям улы (10.1.1960, Чирмешән р-ны Кара Чишмә а.), сәламәтлек саклауны оештыру өлкәсе белгече, мед. фән. д-ры (1999), проф. (2004), РФнең Сәламәтлек саклау отличнигы (2011). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), шунда ук эшли, 1984 елдан социаль гигиена һәм сәламәтлек саклауны оештыру, 1996 дан иҗтимагый сәламәтлек һәм сәламәтлек саклауны оештыру кафедраларында, 2014 тән медицина-профилактика ф-ты деканы. Фәнни эзләнүләре аллергия авыруларының мед.-социаль проблемаларына һәм авыруларны кисәтүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЧЕЛНОКО́ВА** Татьяна Александровна (18.12.1957, Архангельск ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2012). 1982 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1982 дән Яшел Үзән р-ны мәктәпләрендә укыта. 2001 дән Казан инновацион ун-тының Яшел Үзән ф-лында социаль-гуманитар һәм пед. фәннәрен укыта, психол. һәм пед. каф. мөдире (2005), 2008 дән фән эшләре буенча директор урынбасары. Хезмәтләре укучы һәм студентларның шәхси үсеше (ш.и. шәхеснең һөнәри үсеше), инклюзив белем бирү мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**ЧЕРЕВА́ЦКИЙ** Соломон Борисович (20.11.1926, Киев ш.), моторлар төзү белгече, инженер, техник фән. д-ры (1971), проф. (1973). Казан авиация ин-тын (1949), Казан ун-тын (1951) тәмамлый. 1950–71 елларда 16 нчы Казан моторлар төзү з-ды КБда инженер-конструктор, ныклылык бүлеге башлыгы, 1971–91 дә Казан химия-технол. ин-тында материаллар каршылыгы каф. мөдире. Югары ныклыклы җепселләр чорнау алымы б-н булдырылган конструкцияләрне заманча проектлау һәм оптимальләштерү, аларны ясау өчен күп зоналы киләпләр куллану нигезләрен эшли, чорнаулы конструкцияләрне исәпләү өчен тигезләнешләр тигезләмәләрен файдалануны гамәлгә кертә, чорнаулы эшләнмәләр ярдәмендә чорнау алымын куллану мөмкин булмаган җепселле конструкцияләр булдыру ысулын тәкъдим итә. Хезмәтләренең күбесе югары басымлы баллоннар һәм җепселләрне чорнау нәтиҗәсендә булдырулы, диск рәвешендәге энергия туплау чыганакларын проектлау мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 10 нан артык патенты бар.

**ЧИГЛИ́НЦЕВ** Евгений Александрович (30.12.1955, Хабаровск краеның Советская Гавань ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2009). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук эшли, тарих ф-тында кичке һәм читтән торып уку бүлеге буенча декан урынбасары (1982–86), борынгы һәм урта гасырлар тарихы каф. мөдире (2002–13), Халыкара мөнәсәбәтләр ин-тында гомуми тарих каф. мөдире (2013 елдан).

**ЧУЙНО́В** Роман Евгеньевич (2.10.1974, Казан), солист-инструменталист (фортепиано), ТРның халык артисты (2019). Казан консерваториясе каршындагы махсус урта музыка мәктәбен (1992), Казан консерваториясен (1997) тәмамлый. Татар филармониясенең солист-инструменталисты (1995 елдан). ТРда, РФдә һәм чит илләрдә — Франция (Париж), Чехия (Прага, Брно) һ.б.да концерт номерлары б-н чыгышлар ясый (елына 100дән артык концерт бирә). И.Шакиров исем. Халыкара татар җырын башкаручылар конкурсы лауреаты (2005). М.Җәлил шигырьләренә язылган җырлар һәм романслар видеоантологиясен әзерли (2018; Э.Җәләлетдинов б-н берлектә). Медаль б-н бүләкләнә.

**ШАРЫ́ПОВА** Наилә Хабибрахман кызы (24.3.1959, Пермь өлкәсенең Кизел ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2004), проф. (2006). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1981). 1981–96 елларда Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында, 1996 дан Казан аграр ун-тында (1997 тә татар һәм рус телләре кафедрасын нигезли һәм 2013 кә кадәр мөдире була, аның җитәкчелегендә татар теле предмет буларак укытыла башлый). Хезмәтләре рус-татар контактологиясе, икетеллелек, татар һәм рус сөйләме культурасы, социолингвистика, телләрне укыту ысуллары мәсьәләләренә карый, ш.у. Казан а.х. академиясендә белем алучы татар һәм рус телле студентлар өчен татар теле курсы буенча программалар авторы.

**ШАҺИДУ́ЛЛИН** Рифгать Роальд улы (7.10.1961, Казан), химик, эколог, физика-матем. фән. канд. (1990), химия фән. д-ры (2012), ТР ФА мөхбир әгъзасы (2016), ТРның атказ. экологы (2016). Казан ун-тын тәмамлый (1983). 1983–94 елларда РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында: стажёр-тикшеренүче, инженер, өлкән инженер, кече фәнни хезмәткәр, фәнни хезмәткәр, өлкән фәнни хезмәткәр. 1994–2008 дә ТР Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Үзәк махсуслаштырылган аналитик контроль инспекциясе башлыгы. 2008–10 да ТР ФА Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары ин-тында фән эшләре буенча директор урынбасары, 2010 нан директор. Хезмәтләре әйләнә-тирә мохит объектларына кеше эшчәнлеге тәэсирен бәяләү һәм көйләүнең физик-химик аспектлары өлкәсенә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**ШӘЙБӘ́КОВА** Дәминә Дисингали кызы (22.4.1956, Оренбург өлкәсенең Первомайский р-ны Донгуз станциясе), тел галиме, педагог, филол. фән. д-ры (2006), проф. (2007). Казакъ ун-тын тәмамлаганнан соң (Алма-Ата, 1978), Җизказган пед. ин-тында укыта. 1993 елдан Алма-Атада, Казакъ халыкара мөнәсәбәтләр һәм дөньяви телләр ун-тында эшли. 2008 дән «Туран» ун-тында, каф. мөдире. 2011 дән Ю.Либих исем. Гиссен ун-ты профессоры (ГФР). 2013 тән Казакъ милли пед. ун-тында, рус теле һәм әдәбияты каф. профессоры. Тел белемендә караган хезмәтләр авторы.

**ШӘЙМӘРДА́НОВ** Равил Шамил улы (1.7.1940, Мөслим р-ны Ташлыяр а.), хирург, мед. фән. канд. (1982), ТАССРның, РФнең атказ. табибе (1985, 2001), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), Мөслим үзәк район хастаханәсенең хирургия бүлеге мөдире булып эшли. 1970 елдан Казан шәһәре 5 нче клиник хастаханәсендә, 1974 тән кичектергесез хирургия бүлеге мөдире. 1980 нән Казан мед. академиясендә, 1986–92 дә проректор, 1992–2008 дә кичектергесез хирургия каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1980–93 тә, Казан шәһәре сәламәтлек саклау бүлеге баш хирургы. Хезмәтләре бавыр һәм үт юлларының хирургик авырулары очракларында диагноз кую һәм авыруларны дәвалауга карый. Дәүләт бүләге кичектергесез абдоминаль хирургия өлкәсендә яңа технологияләр эшләү һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 11 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘЙХРАЗИ́ЕВ** Васил Габтелгаяз улы (3.2.1963, Минзәлә р-ны Сәет а.), дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе. СССР Эчке эшләр министрлыгының Югары юридик читтән торып уку мәктәбен тәмамлый (1990). 1983–93 елларда РТ Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәрендәге органнарында эшли. 1993–95 тә «Чаллыбанк» АКБнда хокук идарәсе башлыгы. 1995–2003 тә «Чаллы» финанс компаниясе» ҖЧШ директоры. 2003–05 тә Чаллы шәһәр хакимияте башлыгы ярдәмчесе, беренче урынбасары. 2006 дан Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма ком-ты рәисе, 2010 нан Чаллы шәһәре мэры. 2014 тән ТР Премьер-министры урынбасары, бер үк вакытта, 2017 дән, Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы рәисе. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ШӘКУ́РОВ** Фәрит Наил улы (14.10.1962, Бөгелмә р-ны Карабаш пос.), тарихчы, тарих фән. канд. (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1985), шунда ук эшли, 1988–91 елларда фәнни-тикшеренү археография лаб-ясендә кече фәнни хезмәткәр; 1991–2004 тә Чаллы пед. ин-тында, доцент. 2004–11 дә Казан финанс-икътисад ин-тында, 2011 дән Казан ун-тында. Хезмәтләре татар тарихи фикере, татар вакытлы матбугаты тарихы һәм библиографиясе, әдәби чыганакларны өйрәнү мәсьәләләренә карый.

